Далее перевод не отходит от оригинала. На этом отрывке текста мы видим, что в переводе были сокращены некоторые детали, которые бы дополнили сказку и дали бы представление, что утка говорила со всеми, а не только с конкретными названными в русском переводу зверями.

В переводе отрывка сказки: *Бердәнбер көнне йорт хуҗасы үзенең этен иярткән, корыч балтасын биленә кыстырган да урманга киткән. Йортындагы һәрбер кош-кортына: «Өйдә юклыгымны берәүгә дә белдермәс булыгыз!» — дигән. - One day the master of the house went hunting and took his faithful dog with him, and strictly ordered his pets* [Ганиев, 2015:32].

В оригинальной версии речь идет о том, что хозяин взял топор и пса, пошел в лес. Но в переводах на русский и английский – крестьянин оказывается охотником, который пошел охотиться. Наказ хозяина был переведен верно. Но далее упущен момент, когда утка не понимает почему хозяин велел молчать о том, что его и собаки нет дома. *«Нигә белдермәскә кушты икән?»— дип, үрдәк йөдәп чыккан, ләкин ни өчен икәнен һич төшенә алмаган* [Ганиев, 2015:32]. Далее в переводе на английский язык появляется новый персонаж, который в оригинале не упоминается: *Noisy rooster*. Там упоминается, что животные приняли совместное решение отправить за хозяином утку. Но в переводах ее на поиски крестьянина отправляется петух. Слова, с которыми был решено выбрать именно Болтливую утку, переведены дословно: *«Син очасың да, син йөзәсең дә, син йөгерәсең дә, син бар!» : she can walk on the ground, fly through the air and float on the water* [Ганиев, 2015:32].

Далее по тексту также можно увидеть, что переводчики решили опустить некоторые эпитеты. Возможно это вызвано тем, что ни в русском ни в английском языке нет аналогичных эпитетов для передачи художественного слова автора.

В оригинале текста при описании начала путешествия утки по лесу говориться о том, что она гонялась за бабочкой, когда встретила ежика. Но в переводах речь уже идет о том, что утка шла покрякивая. *Үрдәк күбәләк куып йөргәндә, аның каршысына бер Керпе килеп чыккан һәм аңа сүз дә кушкан. - The woods were dense and dark. The Talkative duck was walking and quacking* [Ганиев, 2015:32].

Также мы снова видим нестыковку: в русском и английском переводе хозяин ушел на охоту, а в оригинальной версии он ушел в лес за дровами: *Көннәрдән бер көнне йорт хуҗасы үзенең этен иярткән, корыч балтасын биленә кыстырган да урманга киткән.- One day the master of the house went hunting and took his faithful dog with him, and strictly ordered his pets* [Ганиев, 2015:32].

Также при переводе была упущена следующая деталь: *— Синең өең еракмы соң?— дигән керпе.—Анда симез тычканнар, усал еланнар юкмы? — дип сораган.* правильный перевод должен был звучать так: - А твой дом далеко? – спросил ежик. – У вас водятся жирные мыши и нет ли злых змей. - And how far is your house? — the Thorny hedgehog asked — And do you have any fat mice in there, by any chance? The Thorny hedgehog was very hungry [Ганиев, 2015:32].

При переводе авторы опустили деталь, которая касалась змей. Они сделали акцент на том, что ежик был голоден и поэтому его интересовали только мыши.

Далее в тесте перевода мы не однократно замечаем, что лесоруб превращается в охотника. Это видно из текста, где в оригинале утка спрашивает у медведя, не видел ли он мужика с топором, но перевод отличается и там речь уже идет о мужике с ружьем. Сүз ахырында Аюдан сораган: *Эт иярткән, кулына балта тоткан кешене күрмәдеңме? - The Talkative duck woke the Bear up and told him the whole story and then she asked him:*

— *Have you met a person here with a shotgun and a dog?*[Ганиев, 2015:32].

В отрывке о встрече утки с волком опять при переводе был упущен эпитет, который бы придал более яркую окраску тексту.

В конце сказки, осталась не ясной судьба утки. В оригинале текста речь идет о том, что утка смогла вырваться из лап хитрой лисы, но в переводах говориться о том, что лиса заперла ее в норе.

Следует отметить, что замены – наиболее распространенный и многообразный вид переводческих трансформаций. В процессе перевода замене могут подвергаться грамматические единицы – формы слов, части речи, типы синтаксической связи и т.д. Замена компонентов словосочетаний при переводе приводит к изменению его синтаксической структуры. Можно отметить, что субстантивные словосочетания с прилагательным в качестве зависимого слова на татарский язык переводятся в форме изафета второго типа, порядок слов не меняется, зависимое слово выражается существительным.

В татарском языке нет категории рода. Например, местоимение «ул» означает и он, и она, и оно. Ударения в словах стоит на последнем слоге, исключения составляют заимствованные слова.

В предложениях глаголы и слова, от них образованные, стоят всегда в конце. Прилагательные располагаются строго перед существительными. Интересно и употребление форм глаголов прошедшего времени. Одна форма глагола употребляется, если человек рассказывает о событиях, которые произошли непосредственно с ним, и другая при рассказе о событиях, которые говорящий пересказывает с чужих слов.

Татарский язык имеет богатую лексику и фразеологию. Татарские пословицы трудно перевести на русский, они теряют при этом мелодичность. Но мудрость остается.

Основной принцип полноценного перевода изобразительных средств заключается в наиболее полной передаче значения и художественных особенностей – образности, эмоционально-экспрессивной силы оригинала при одновременно строгом соблюдении норм языка. Данный принцип предполагает 4 основных способа перевода тропов: 1) дословный перевод или калькирование; 2) перевод с некоторым изменением отдельных компонентов; 3) адекватная замена; 4) компенсация.

Вывод: стоит отметить, что Абдулла Алиш является обладателем весьма специфического слога, который не всегда можно передать на другом языке. Это ярко подчеркивается по сказке «Болтливая утка». В этой сказке очень много эпитетов и специфических оборотов, которые не имеют аналогов в других языках. Его сказки написаны понятным простым языком, который будет понятен, для детей разных возрастов.

## АНАЛИЗ СОДЕРЖАНИЯ АНГЛИЙСКИХ НАДПИСЕЙ НА ФУТБОЛКАХ ПОДРОСТКОВ.

*Шаяхмедова Адиля, ученица 11 класса,*
*Научный руководитель: Галимулина Лилия Ракиповна*
*МБОУ «СОШ им. Г.Г.Гарифулина с. Ядыгерь» Кукморского муниципаьного района РТ*

В наше время молодежь любит выделяться. Одной из выделительных черт являются надписи на одежде. Сейчас подростки стараются купить такие вещи, чтобы на них было написано яркими большими иностранными словами.

Проблема заключается в том, что не все знают, какую смысловую нагрузку несут надписи на одежде.

Моя работа посвящена исследованию содержания английских надписей на футболках подростков.

Актуальность выбранной темы состоит в том, что футболки с надписью стали неотъемлемой частью гардероба современного человека. Футболка стала в некотором смысле трибуной, с высоты которой человек имеет возможность сказать всему миру о специфике своего характера.

Новизна данной исследовательской работы определяется изучением и выявлением содержания английских надписей на футболках.

Объект изучения - надписи на футболках на английском языке.

Предметом исследования является информация, которую несут надписи на футболках.

Цель работы – установить зависимость смысловой нагрузки надписей на футболках от уровня владения английским языком.

Задачи для достижения поставленной цели:

1. Изучить научную литературу по вопросу.
2. Провести социальный опрос среди учащихся, чтобы узнать самые популярные надписи на футболках.
3. Осуществить перевод на русский язык популярные надписи на футболках.
4. Выявить возраст обладателя надписи на футболке.
5. Проанализировать собранный речевой материал и прийти к определенному заключению.

Гипотеза - данная работа полезна тем, что учащиеся школы после исследования английских надписей на футболках будут серьезнее подходить к выбору одежды с надписями.

Работа проводилась поэтапно:

1. Составление основной информационной работы.
2. Проведение анализа и сравнения собранных надписей.
3. Обозначение выводов и результатов работы.

При написании научно-исследовательской работы применялись следующие методы: экспериментальный для проведения анкетирования и определения зависимости надписи на футболке от возраста тинэйджера; поисковый и описательный, предполагающий анализ языковых факторов; аналитический, предполагающий сопоставительный анализ отобранных надписей.

Моя работа делится на две части: теоретическую и практическую. В первой части я рассмотрела такие элементы, как историю появления надписях на одежде, потребность людей носить футболки с надписями. Во второй части работы представлены результаты обработки полученных анкет, лингвистической экспертизы надписей.

Футболка – это предмет одежды, в которой отсутствуют пуговицы, воротник и карманы. Этот предмет одежды появился впервые в Северной Америке, как это ни удивительно, во времена Первой мировой войны, когда американским солдатам нужно было легкое нижнее белье из хлопка.

Само слово футболка – исключительно русское, а исконное название этого предмета гардероба – T- shirt, что в дословном переводе звучит как «т-образная рубашка». В СССР слово «футболка» пришло, как определение верхней части формы футбольного игрока.

Надписи на одежде существовали еще много веков назад. И самые ранние знакомы нам по Древней Греции. Затем их можно заметить на множестве итальянских и немецких портретов конца XV и XVI веков, надписи вплетены в орнамент мужских рубашек, в корсажи женских платьев, где обычно написаны на латыни или девизы знатного рода, или

имена владельцев этих портретов или нарядов. А если говорить о периоде более современном, то надписи украшали форму рабочих, указывая на их статус на рабочем месте, потом они стали показывать какого дизайнера или какой фирмы эта вещь, а уже после этого стали появляться надписи, которые в самом деле несут смысл. Неизвестно, кто первый придумал писать надписи на одежде.

Надписи бывают разные и меняются по мере взросления человека. У ребенка это просто какое-то забавное словечко, у подростка – цитаты, реплики киногероев, громкие и пафосные лозунги, граничащие иногда даже с непристойностями. Взрослые же люди, понимая, что на одежде может быть написано что-то не для их возраста или что-то непристойное, стараются выбирать одежду без надписей - это верное решение, в отличие от подростков, которые только и смотрят на красивый фасон и веселые буквы. Ну что ж, будем снисходительны к тинэйджерам– для их самоутверждения любые средства хороши! С годами все мы к выбору написанного на одежде относимся серьезнее и хотим, чтобы слова выражали наши истинные убеждения или намекали на что-то потаенное.

Молодежь, возможно, не поверит, но те, кто постарше, наверняка подтвердят, что два десятилетия тому назад и раньше появление на улице человека в одежде с непонятной надписью на английском означало в глазах общественности не что иное, как провокацию и вызов. Тем не менее, все тайком завидовали обладателю импортной вещички, не побоявшемуся выделиться среди масс. Другое дело - сегодня! И дети, и молодые, и не очень молодые люди носят одежды с английскими надписями – все воспринимают их как стильный элемент отделки.

Многие стремятся купить одежду с надписями исключительно на иностранном языке. Что они хотят этим сказать? Если ничего, то это действительно дань моде. Но футболка – еще и словно чистый лист, на котором можно начертать. Только к надписям на футболках на английском надо относиться осторожно, потому что умная мысль прозвучит нелепо, если неправильно сформулировать ее на чужом языке. То же самое можно сказать и о стандартных готовых фразах – неудачно подобранные станут не чем иным, как казусом в одежде.

Мы в ответе за то, что написано у нас на одежде.

К надписям на одежде следует относиться настороженно. Окружающие воспринимают их зачастую, как слова, произнесенные вслух хозяином модной одежды. Если ты не поддерживаешь написанные на твоей одежде слова, зачем ты ее нацепил на себя? Не так давно по этому поводу разгорелся целый международный скандал, затронувший Германию и Китай. За последние пару лет зафиксировано почти два десятка случаев, когда за непонятные надписи на майках, выполненные на арабском языке, или понятные, на английском, но с "шутками" по поводу бомб, носителей такой одежды секьюрити не пропускали на рейс в самолет. Таким образом, перефразируя знаменитую фразу, можно утверждать – мы в ответе за то, что написано у нас на одежде.

Среди 5-11 классов нашей школы было проведено тестирование по вопросам:

–возраст носителя;

–носит ли футболки с надписями на английском языке;

–почему приобрел эту вещь;

–знает ли о смысле написанного на одежде или нет (напишите, если знаете);

Результаты опроса учащихся. Я проанализировала результаты 40 учащихся.

Ответы на вопрос носите ли вы футболки с надписями на английском языке анкетируемые ответили следующем образом:

37 опрошенных из 40 отметили, что носят футболки с надписями на английском языке.

На вопрос почему вы приобрели эту вещь учащиеся ответили по - разному. Большая часть учащихся ответила, что понравился цвет и большие буквы, одни специально искали вещи с иностранными надписями, а другие приобрели её только потому что она понравилась.

Ответы на четвертый и пятые вопросы анкеты выглядят следующим образом:

В результате исследования я выяснила, почти у всех есть как минимум две вещи с иностранными надписями. Из всех опрошенных 19% не знают, что написано на футболке, а остальные 81% понимают смысл надписей. Из этих 19% учащихся 15% составляют те, которые неправильно понимают, что за информация у них на одежде, а остальные 4% не пытаются её понять

Ответы на пятый вопрос мы разместили в следующей таблице. Для полного осмысления мы разбили надписи на группы по темам:

1.Романтика

| Надпись в оригинале | Перевод | Возраст носителя | Знает о смысле или нет? |
|---|---|---|---|
| 1.Loveforever | Вечная любовь | 13 | + |
| 2.Love | Любовь | 13 | - |
| 3.Justforyou | Только для тебя | 14 | + |

2.Города и страны

| | | | |
|---|---|---|---|
| 4.Russia | Россия | 15 | + |
| 5.New York | Нью – Йорк | 16 | + |
| 6.Paris | Париж | 14 | + |
| 7.London | Лондон | 17 | + |

3.Дизайнеры и бренды спортивной одежды

| | | | |
|---|---|---|---|
| 8. Nike | | 16 | - |
| 9. Reebok | | 17 | - |
| 10. D&G | | 16 | + |
| 11. Adidas | | 16 | + |

4.Разное

| | | | |
|---|---|---|---|
| 12. Baby | Малыш | 15 | + |
| 13. Magic | Магия | 16 | + |
| 14. Morning Star | Утренняя Звезда | 13 | - |
| 15. Home sweet | Милый дом | 17 | + |

5. Кредо

| | | | |
|---|---|---|---|
| 16. Darling | Любимый | 15 | + |
| 17. Best friends | Лучшие друзья | 17 | + |
| 18. Angel | Ангел | 17 | + |
| 19. Superstar | Супер звезда | 17 | + |
| 20. Freedom | Свобода | 17 | - |
| 21. Justice | Справедливость | 17 | - |

6. Призыв

| | | | |
|---|---|---|---|
| 22. Do not copy me | Не копируй меня | 15 | + |
| 23. Don’t read my T-shirt | Не читай с моей футболки | 15 | + |
| 24. Kiss me | Поцелуй меня! | 12 | - |
| 25. Look at me | Посмотри на меня | 15 | - |
| 26. See you | Увидимся | 17 | - |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 27. Don’t forget me | Не забывай меня | 16 | + |
| 28. Get away | Уйди! | 15 | - |
| 29 .Think a little | Подумай немного | 15 | - |

Так же хочется особо подчеркнуть: во время исследования не были выявлены ошибки в надписях на футболках.

Между знающими и не знающими процент разницы не большой, но все равно к покупке одежды с надписями нужно подходить серьезнее, так как вещи отражают характер человека и его внутренний мир. После тестирования, учащиеся подчеркнули, что теперь при покупки вещей будут больше обращать внимания на словосочетания и буквы, украшающие одежду.

Надписи на одежде существовали еще много веков назад. И дети, и взрослые люди носят одежду с надписями на английском – все воспринимают их как стильный элемент. И это действительно дань моде. Только к надписям на футболках надо относиться осторожно, потому что умная мысль прозвучит нелепо, если неправильно сформулировать ее на чужом языке. Мы в ответе за то, что написано у нас на одежде.

Мы достигли цели, так как выяснили: культура самого человека неразрывно связана с его языковым уровнем.

# ГАЗЕТА ҺӘМ ЖУРНАЛЛАРДА СТИЛИСТИК ХАТАЛАР

*Әкбиров Илһам Илшат улы, 10 нчы сыйныф укучысы*
*Фәнни җитәкчесе: Гайнанов Руслан Наил улы,*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы*
*МБГБУ "Кукмара ш.т.п. А. М. Булатов исемендәге күппрофильле лицей",*

Вакытлы матбугат җәмгыятьтәге бөтен үзгәрешләрне, яңалыкларны чагылдырып бара. Билгеле, «җәмгыятьтә барган үзгәрешләр, яңа төшенчәләр барлыкка килү һәрваккытта да телдә яңа сүз тууга китерми». Еш кына бу процесс озак бара: алдан ул ничек тә булса барлыкка килә, аннары гына башка журналларда һәм газетларда кулланыла башлый. Шулай, вакытлы матбугатта сынау үткәч кенә, сүз академик сүзлекләргә керә. Шуңа күрә вакытлы матбугат телен өйрәнү, аны классификацияләү – тел белгечләре алдында тора торган мөһим бурычларның берсе.

Вакытлы матбугатта тел проблемаларын, бигрәк тә анда киткән стилистик хаталарны тикшерү җәмгыять өчен бик тә зарур. Чөнки тел проблемалары – ул халык проблемалары, ә бүгенге көн татар милләте өчен әһәмиятле замана, үзгәрешләр, реформалар заманасы.

Хәзерге татар телендә зур үзгәрешләр бара. Күбесенчә алар объектив сәбәпләр нигезендә, ләкин кайбер проблемалар (орфография мәсьәләләре) журналлар һәм газетлар битләрендә бөтен укучылар арасында каралырга тиеш. Шуңа күрә вакытлы матбугаттагы телгә багышланган саф лингвистик һәм фәнни-популяр очерклар булырга тиеш, һәм аларны анализлау шулай ук әһәмиятле.

Хезмәтемнең өйрәнү объекты: хаталар очраган матбугат чаралары.

Өйрәнү предметы: матбугаттагы еш очрый торган стилистик хаталар.

Төп максаты телдәге стилистик хаталарны анализлау, нинди ялгышлар ешрак очраганын ачыклау.

Бу максатка ирешүдә түбәндәге бурычлар куелды:

1."Ватаным Татарстан" газетасын һәм "Идел" журналын стилистик хаталарга тикшерү.

2. Татар матбугатының тел мәсьәләләренә карата карашын ачыклау.

3. Сәяси-иҗтимагый мәкаләләрдә тел проблемаларын карау.

Гипотеза: Стилистик хаталар проблемасы гына татар сөйләмен үстерә ала Һәм бары тик бу проблеманы күтәрү аны ачыклый.

Бу теманы киңрәк карарга да мөмкин. Чөнки матбугаттагы стилистик хаталар мәсьәләләре кызыклы темаларның берсе һәм бу беребезне дә битараф калдырырга тиеш түгел.

Хезмәткә безнең тарафтан татар теленә һәм гомуми тел белеменә караган терминология кулланды. Кайбер сорауларны ачыклау максаты белән без берничә теоретик материал куллandык.

Тел кануннары матбугатта барлыкка килә. Шуңа күрә вакытлы матбугатта телдәге хаталарга багышланган материаллар да, аны бетерү юлларын укучылар белән бергәләп эзләү дә игътибарга лаек. Бу кечкенә хезмәтем, әлбәттә, зур проблемаларны хәл итә алмый. Ләкин теманың актуальлеген ачыкларга ярдәм итә.

Хезмәт керештән, төп өлештән йомгаклаудан һәм әдәбият исемлегеннән тора. Керештә эшнең максатлары куела, актуальлеге дәлилләнә. Төп өлеш алга куелган "Газета һәм журналлардагы стилистик хаталарны" анализлауга багышланган. Монда телне куллануда уңай яклары һәм кимчелекләр билгеләнеп үтә. Йомгаклауда тема буенча төп нәтиҗәләр күрсәтелгән.

*“Ватаным Татарстан” газетасы һәм “Идел” журналында еш очрый торган хаталар*

Хәзерге заманны матбугатсыз күз алдына да китереп булмый. Мәгълүмат мәйданы искиткеч зур. Елның-елында әлеге мәйданда берсеннән-берсе яңа газеталар һәм журналлар пәйда була тора. Тик шунысы бар, әлеге матбугат чаралары арту белән, аның сыйфаты түбәнәя бара. Без биредә дә сан ягыннан куып, сыйфат дигән төшенчәне онытa барабыз бугай. Ә бит матбугат чаралары безнең яшәешебезнең көзгесе, тормышыбыз чагылышы булып торучы бер чара.

Шунысы аянычлы, газета-журналларның эчтәлеге генә саекмыйча, хаталар да күбрәк китә башлады. Бүгенге көндә вакытлы матбугатта телнең бозык булуы, аларда стилистик хаталарның бик күп булуы борчылу тудыра. Газета, журнал битләрендә кайчандыр ялгыш тәрҗемә ителеп яки төгәл тәрҗемә ителмәгән сүзләр еллар буена язылып килә. Әйтик, матбугаттагы стилистик хаталар үзенчәлекләре телдәге мәсьәләләрне шактый ачык билгелиләр.

Бу хезмәтемдә мин «Ватаным Татарстан» газетасының һәм “Идел” журналының стилистик хаталарына игътибар иттем. Газета һәм журналлардагы язма тел шундый иркен куелган ки, кем нәрсә язарага тели, шуны яза, ничек җиңел шулай “сырлый”. Нәтиҗәдә автор үзе генә белгән, үзе уйлап чыгарылган сүзләр туа. Мәсәлән: “тәкыя” (такыя), “мәшәкәт” (мәшәкать), “хәкимият” (хакимият), “сүде” (сода), “хәттә” (хәтта), “ гәйбәт” (гайбәт), “тавар” (товар), “мөгәен” (мөгаен), “бөкере” (бөкре), “коерык” (койрык), “ахырсүз” (ахыр сүз), “йодырык” (йодрык), “үтәкүренмәле” (үтә күренмәле), “егетчак” (егет чак), “тәккәбер” (тәкәббер), “аппарганда” (алып барганда), “әлләкем” (әллә кем), “пакьлык” (пакълек) һ.б. бик күп “ яңа” сүзләр барлыкка килде.

Эш аерым сүзләрнең ялгыш язылуларында гына булса бер хәл иде, хәзер инде җөмлә төзелешендә дә хаталар шактый күп очрый.. Менә берничә генә мисал.

“Бөек Ватан сугышы өчен барган сугышта тылдагы халык җиңеп чыгу өчен үзе ач калса да, һич нәрсәне кызганмады”. Бу җөмләдә мәгънәсезлек тә ята кебек: Бөек Ватан сугышы өчен сугыш бармый бит инде. (Барса, Бөек Ватан өчен барырга мөмкин ул сугыш), ике җирдә дә ноктада “Онытылп” калган, һич нәрсә (һичнәрсә) ялгыш язылган, бер җөмләдә ике “өчен”, ике “сугыш” сүзен куллану да күңелле күренеш түгел.

“Башта карышып торды: поезд хәзер эшелонга тоялеп, бик еракка китәчәк...”. Монда да мәгънәсезлек килеп чыккан. Эшелонны поездга төяп буламы? Чөнки эшелон шул ук тимер юл составы, икенче төрле әйтсәк, поезд бит инде!

“...уеннан яшен тизлеге белән бер уй үтте: үтерергә!” Бәлки “башыннан... уй үтте” дияргә кирәк булгандыр?

“Алар хуҗалыгында алты мөгезле эре терлек бар”. Бу җөмләдә автор алтыдан соң “баш” сүзе куйса, алты мөгезле эре терлек турындагы мәгънәсезлеккә урын калмас иде.

Бик күңелсез бу күренешнең инде газета битләреннән журналларыбызга да үтеп керүе аянычлы хәл.

Журналларыбыздагы кайбер язмаларның татар телендә түгел, ә урысчалы-татарчалы катнаш телдә язылуы һәм басылуы гаҗәпкә калдыра. Стилистик хаталар гадәттә рус теленнән кергән яңа алынмаларда очрый. . Мәсәлән: «Бу – вольерларда ялтыравыклы компьютер компакт-диск элеп кую» [«Иң яхшы күркә – тыныч холыклы», № 64]; «Шул ук брифингта республика идарәсенең салым түләүчеләрне исәпкә алу бүлеге начальнигы Ольга Агафетованың әйтүенчә, быел барлык салым түләүче, юридик затларга салым түләүченең идентификация номеры (ИНН) биреләчәк» [«Фатир сатып алырга булсаң, кайдан акча алуыңны дәлилләү турында уйла», № 58]. Аерым сәясәт өлкәсендәге неологизмнарны билгеләп китәргә була. Мисаллар: «Комиссиядә ел саен уртача 180 федераль закон проекты, федерациясенең башка субъектларындагы коллегаларның 50гә якын закон тәкъдим итү инициатива-мөрәҗәгате тикшерелде» [Кеше сызлануын үзеңнеке кебек той, № 56]; «Ватаным Татарстан» газетының рус теленнән алынган калькалар белән мавыгу – аның аеруча бер үзенчәлеге дип санарга мөмкин. Еш кына сәяси-иҗтимагый өлкәдә идиомага

әверелгән сүзтезмәләрне әйтеп китәргә кирәктер: «Беренче ел хезмәт итүче солдатларның моннан соң «кайнар ноктлар»га җибәрелмәячәге өчен аналар нәкъ менә аңа рәхмәт әйтә алалар» [«Милли мәдәният үзенчәлекләре», № 64]; «Ачуы чыккан хатын кухнядан зур пычак ала да иренең аркасына кадый, аннары шул ук пычак белән иренең корсагына удар ясый да «ашыгыч ярдәм»гә мөрәҗәгать итә» [«Өченче бала кирәкме?», № 58]. Рус теленнән еш кына сүзләр кушылып ясалган терминнар да кабул ителә. Мәсәлән: «Бер айга якын сузылган тәнәфестән соң суперлига хоккей командалары чемпионатны дәвам итте» [«Хоккей», № 54];

Аерым бер үзенчәлек итеп рус теленнән кергән алынмалар нигезендә яңа фигыльләр ясалуы да игътибарга лаеклы. Мәсәлән: «Массакүләм мәгълүмат чаралары киләчәктә дә җәмгыятьне туплауның һәм халыклар арасындагы мөнәсәбәтләрне гармонияләштерүнең куәтле факторы булып хезмәт итәчәгенә ышанабыз», – дип билгеләп үтелә» [«Журналистлар бәйрәме», № 67]; Башка вакытлы матбугат чараларындагы кебек үк «Ватаным Татарстан» газетында еш кына рус теленнән алынган яңа сүзләргә җәяләр эчендә аңлатма бирелә. Шулай, «Корылык һәм башка катаклизмнар (кискен үзгәрешләр) көтелми» [Җәй ничек килер?», № 67].

“Бүген проба токымы алырга килделәрме?” –дип укыгач, ирексездән, бу урысча уйлап язылган җөмлә, дип куясың. Биредә бит “проба породы”ның “ порода”сүзе генә тәрҗемә ителгән.

Мондый ише тәрҗемәсез сүзләр газеталар да, журналларда да очрый тора. “Особняк”, “щитовой бараклар”, “зарплата”, “ведомость исемлеге”, “отгул”, “недобор”, “контролировать” кебек сүзләрнең тәрҗемә итеп тә биреп була югыйсә.

Әлбәттә, бу тема аеруча әһәмиятле, һәм ул бүгенге чордагы тирән үзгәрешләр белән бәйле. Мәсәлән, “Ватаным Татарстан” газетасының кайбер саннарындагы «Түгәрәк өстәл» артында сөйләшү, чүп үләне, уңыш астына ашлама кертү кебек сүз терминнарына гына игътибар итик әле. Урысчадан калькалаштырылган әлеге кызыклы мисаллар рәтенә тагын башкаларны да өстәп булыр иде: «Семена», «без потерь» – орлыклар, югалтуларыбыз. Бу очракта «лар»ы артыграк кебек. Орлык, югалтусыз, дип уңайрак та, күңелгә дә ятышлы булыр иде. Әлбәттә, монда грамматик калька хата булып килә.

Бүгенге көндә матбугатта бәхәсле булып кала бирә торган сүзләр күп әле. Әйтик, повар – пешекче, предпринимательство – кәсәбәчелек, кәсепчелек. Гадәттә поварны пешекче дип тәрҗемә итәләр. Ләкин аны ашчы дип язучылар да очрый. Предприниматель сүзен кайберәүләр эшкуар, эшмәкәр дип тәрҗемә итә. ... Эшмәкәр – эшчән, уңган, эшлекле дигәнне аңлата. Халыкта эшмәкәрне бал басар, эшлексезне йокы басар дигән әйтем бар. Эшкуар, дисәк, дөресрәк тә булыр иде кебек. Аңлатмалы сүзлектә эшкуар сүзе – эшләрне (бигрәк тә коммерция эшләрен) бернинди ысулдан да чирканмыйча, оста итеп алып баручы, дигән мәгънәдә бирелә. Предпринимательгә килгәндә, аны малтабар, малкуар, дип әйтергә тәкъдим итүчеләр дә бар.

Газета битендәге “решение принимать иттелде”, яңа йорт сдавайт ителде”, “школага йөриләр”, “пригласительный билет бирделәр”, “взаиморасчетлар ясау”, “эшнең качествосына карап” сүзләре газетаның да, журналларның да йөзен бизәми.

Вакытлы матбугаттан тагын мисаллар китереп китик. Хәзер кайбер матбугат басмаларында поселок сүзен бистә дип йөртү китте. Бистәнең «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә ике төрле мәгънәсе бар. Шуның безнең кулланышта йөри торганы – «шәһәрнең аерымрак урнашкан өлеше, «районы». Мондый бистәне урыслар «слобода» дип йөртә. Ә нигә соң әле безнең поселок бистәгә әйләнеп китте. Поселокның үз мәгънәсе бар лабаса: шәһәр яки зуррак авыл тирәсендә урнашкан шәһәр тибындагы зур авыл.

Тел – иҗтимагый күренеш. Сүзләрнең мәгънәләре киңәя, үзгәрә, тарая. Сүзләрдә яңа мәгънә туу билгеле. Әйтик, хәзер кесә телефоны (сотовый телефон) да матбугат битләрендә төрлечә бирелә. Бездә аны берәүләр күзәнәкле телефон, икенчеләре – кәрәзле телефон дип йөртә. Урысчадан төп-төгәл тәрҗемә итим дисәң (безнеңчә – калькалаштырсаң), шулай анысы. Уйлап карыйк әле. Сотовый сүзе *сот, соты* сүзеннән ясалган, кәрәзне аңлата. Сорау туа: бу телефон умартачылыкка ни катнашы бар? Белгечләр болай аңлатты: балга катнашы

юк, телефон номерлары тартмасында бал кәрәзендәге кебек бүлемтекләр күп булганга шулай йөртелә. Алай булса, ник без аны гади итеп – чыбыксыз телефон, яки кесә телефоны дип атамыйбыз соң?

Матбугат үзе телнең чисталыгын якларга өндәп язылган мәкаләлере белән үрнәк булырга тиеш. Тик моңа ирешүдә һаман саен кыенлыклар бар әле. Мәсәлән “Ватаным Татарстан” газетасының бер санында “Саратов губернаторв Дмитрий Аяцков чит телдә язылган вывескалар элеп куюны һәм чит телдән кергән сүзләрне артык күп куллануны тыя торган боерык чыгарган. Минемчә, вывеска дигән сүз урынына алтакта, белдерү тактасы, яки эленмә такта кебек сүзләр кулланырга мөмкин.

«Идел» журналы республикабызның яшьләр матбугат органының берсе буларак телне куллануда бер үрнәге булып тора. Ләкин анда очраган хаталарга карап күнел әрни. Әйтик: «Төрле яшьтәге кешеләр берәмләп тә, төркемләп тә кызу-кызу адымнар белән савыктыргыч прогулкага ашыгалар» [«Биш стакан су һәм чаңгы таяклары», № 4], яисә: «Ачуы чыккан хатын кухнядан зур пычак ала да иренең аркасына кадый, аннары шул ук пычак белән иренең корсагына удар ясый да «ашыгыч ярдәм»гә мөрәҗәгать итә» [«Мәкерле үтереш», № 3. Журнал саннарында географик атамаларда да хата табып була. Мәсәлән, Зеленодольск, Зелёный Дол татар зыялылары арасында һәрвакыт Яшел Үзән дип атала. Бу күренеш татар әдәби теленең нормасына кереп бара. Ләкин әлеге атама журналда гына түгел, газета битендә дә нигәдер Зеленодол дип бирелә: «Әлеге киңашмәдә катнашучылар составы 10 гыйнварда Әлмәт, Арча, Зеленодол, Казан һәм Чаллы шәһәрләрендә узган территориаль җыелышларда билгеләнде» [«Вәкилләр киңәшмәсе», № 59].

«Ватаным Татарстан»газеты битләрендә еш кына уңышсыз яңа сүзләр дә кулланыла. Әлбәттә, аларның уңышсызлыгын вакыт билгели, ләкин алар, кагыйдә буларак, татар теленең закончылыкларына буйсынмыйча текстка керәләр. Әйтик, «Татарча көрәш – спортның милли төрләре арасында иң абруйлы һәм массовый төре» [«Милли көрәш – татарның рухи терәге», № 57]. Бу мисалда «массовый» - масса-күләм, күп кеше катнашкан; күпләп; киң халык (масса) өчен, киң катлау дигән мәгънәне аңлата.

Без караган мисалларда тагын бер үзенчәлекле проблема барлыкка килде. Бу – аббревиатуралар кулланышы. Әйтик, СПИД кебек аббревиатуралар татар теленә кереп, анда үзенең урынын алдылар. СПИД сүзе «Ватаным Татарстан» газетында да, “Идел” журналында да очрый. Ләкин әле тагын яңа аббревиатуралар да очрый. Мәсәлән, ИНН: «Шул ук брифингта республика идарәсенең салым түләүчеләрне исәпкә алу бүлеге начальнигы Ольга Агафетованың әйтүенчә, быел барлык салым түләүче, юридик затларга салым түләүченең идентификация номеры (ИНН) биреләчәк» [«Фатир сатып алырга булсаң, кайдан акча алуыңны дәлилләү турында уйла», №65]. Русча ИНН – идентификационный номер налогоплательщика дип аңлатыла, ә татарча без аны ЧАҖ кебек аббревиатуралар белән беррәттән СТИН – салым түләүченең идентификация номеры дип тәрҗемә итсәк, бәлки, уңышлырак булыр иде.

Мондый очракларда кайберәүләр СТИН аббревиатурасы аңлаешсыз, ә ИНН инде гади сөйләм телендә үз урынын алган сүз диюе бар. Әлбәттә, СТИН сүзе аңлаешсыз булып кала бирә,

«Идел» журналының бөтен материалларында да Россия Русия дип аталу дөрес микән? Ләкин, моның бер формасы да әлегә норматив телгә кермәгән булса да, бөтен дәүләт документларында Россия формасы кулланыла. «Идел» журналы соң бу мисалда Русия яклы. Мәсәлән: «... быел Русиядә бу эшкә алынучылар алдында зур җаваплылык, борчу-мәшәкатьләр торуын күз алдына китерәм мин» [№3]. Шундый ук проблемалар башка топонимик атамаларда очрый. Мәсәлән: «Аның гәүдәсе генә Аурупада, ә рухы, бөтен эчке дөньясы Урал тавы артында калган» [№4].

Татар матбугаты тел мәсьәләләренә карата беркайчан да битараф булмады. Журнал һәм газет битләрендә даими тел белгечләре, галимнәр чыгышлары бастырылып бара. Ләкин соңгы елларда татар теленә карата мөнәсәбәт бераз салкынайды. Туган телне искә алганда,

күбрәк сәяси-иҗтимагый якларны тикшерү башланды. Бу проблема рус матбугатында да бәхәс буларак урын алып тора. Төрле диспутлар, фикерләр еш бастырылып чыга.

Минем уйлавымча, телне саклау, аны куллану өчен үзебезнең газиз туган телебезгә ихтирам, хөрмәт кенә кирәк. Чит илләрдән кергән, тешне сындыра торган сүзләрдән башка да матур сүзләр, чын татарча терминнар кулланырга да була бит.

Күргәнебезчә, вакытлы матбугаттагы күп кенә материаллар эмоциональ стильдә язылып, проблеманың нигезенә карамыйлар. Шуңа күрә, телдәге стилистик хаталарны бетерү проблемалары өстендә эшлисе күп әле.

Шунысын әйтергә кирәк, соңгы вакытта «Ватаным Татарстан» газетасындагы мәкаләләрне анализлаганда стилистик хаталар җибәрмәү өстендә эш алып барылганы сизелә башлады. Гадәттә әлеге хаталар сәяси-иҗтимагый материалларда табыла.

Хезмәтебезгә нәтиҗә ясап шуны әйтәсе килә:

– газета һәм журнал телендәге стилистик хаталар бик аз күләмдә карала:

–сәяси-иҗтимагый мәкаләләрдә тел проблемалары берьяклы гына карала, еш кына асылында дөрес булмаган нәтиҗәләр ясала;

–телне куллануы өлкәсендә бөтен массакүләм мәгълүмат чараларына да әдәби телдәге кануннарны үтәү – закон булырга тиеш: «Ватаным Татарстан» газетасында да “Идел” журналында да топонимик атамаларны кулланганда, минемчә, язылу вариантларына да игътибар итәргә кирәктер;

– матбугатта аерым уңышсыз үзенчәлек булып рус сүзләре һәм алынмалары белән мавыгуны әйтеп китәргә кирәк.

Әлбәттә, вакытлы матбугаттагы стилистик хаталарны даими өйрәнү бик зарур. Бу – бәхәссез. Әмма бүгенге көндә бу темага багышланган фәнни хезмәтләр күп түгел. Аерым темаларны ачыклау өчен, фактик мәгълүмат җыю өчен журналларыбыз һәм газетларыбыз тарафыннан еш кулланыла, ләкин нәкъ вакытлы матбугат текстларына багышланган зур фәнни хезмәтләр юк диярлек.

*Кулланылган әдәбият исемлеге:*

1. «Ватаным Татарстан» газеты. – 2011-2017, апрель-май айлары .
2. «Идел» журналы. – 2011-2017, № 2, 3, 4..
3. Низамов И.М. Уем – тел очында. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1995. – 475 б.

## АВЫЛЫМ ТАРИХЫ БӘЕТЛӘРДӘ

*Әкбирова Назлыгөл Фәргать кызы, 6 нчы сыйныф укучысы*
*Фәнни җитәкче: “Ядегәр авылы Г.Г.Гарифуллин исемендәге урта гомуми белем бирү мәктәбе”нең югары квалификацион категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы*
*Габбасова Гамилә Мәгъсүм кызы*

Бәетләр – татар халык авыз иҗатына хас һәм язма әдәбиятка, аның балладалар төренә бик якын торган үзенчәлекле жанрларның берсе. Бәет сүзе безгә гарәп теленнән кергән, һәм ул шигырь юлы, дөресрәге, ике юллы шигырь дигән сүз. Бу сүзнең татар халык иҗатының эпик бер жанрына исем булып кереп китүе, бәетләрнең баштан ук тезмә рәвешендә иҗат ителүләрен күрсәтә. Татар халык авыз иҗатының бәет жанры –татар халкы менталитетын, хыял, дөнья, ниятләрен киң һәм тирән, бик борынгыдан ук бу көннәргә хәтле, көйләп һәм сөйләп, язма һәм телдән иҗат итү юлы белән бәян ителгән шигъри әсәрләр**.** Алар халыкның үзе кебек үк борынгы заманнарда ук туган. Гасырлар дәвамында бәетләр башка жанрлар белән аралашып үскән, сүрелгән, ләкин сүнмәгән, милли жанр булганга күрә, безнең Фольклор секциясе әлеге әсәрләрне өйрәнүгә, җыюга алынды. Бәетләр дуслар, туганнар белән тату, күршеләр белән килешеп, дошманы белән ызгышмый яшәгән бөек халык

дипломатиясен күрсәтүе, әдәпле, әхлаклы шәхес булырга чакыруы белән әһәмиятле, шуңа күрә аларны өйрәнү **актуаль** дип саналды һәм өйрәнүгә алынды.

Эзләнү эшенә бәетләрнең туган як тарихында тоткан урынын билгеләү **максаты** куелды. Максаттан чыгып, түбәндәге **бурычлар** куелды: бәетләрне кемнәр иҗат итүен, башламнары ничек булуын, аларны өйрәнү мәсьәләсе ничек торуын, тематика ягыннан төрлелеген өйрәнү; бәетче В.М.Әсхадуллинаның иҗатын тематик яктан берләштерү; бәетләр, аны өйрәнүнең бүгенге көндә актуальлеген билгеләү. **Эзләнү объекты**: В.М. Әсхадуллинаның бәетләре.

Фәнни эш: кереш, эчтәлек, төп өлеш, йомгаклау, кулланылган әдәбият, кушымта өлешләреннән тора.

Халыкның тарихын, аның тормышында булган зур һәм катлаулы вакыйгаларны реаль җирлектә яктырта килгән бәетләр, һичшиксез, халык иҗаты, һичшиксез, халык массаларының рухи байлыгын чагылдырган сәнгать әсәрләре.

Бәетләрне иҗат итүдә халыкның барлык катлау вәкилләре: эшчеләр һәм крестьяннар, байлар һәм ярлылар, солдатлар, укымышлылар, ягъни мәдрәсә шәкертләре дә катнашкан. Халык күңеленә ошаган, күп кенә бәетләр телдән телгә күчеп йөрү юлы белән генә түгел, бәлки халык авыз иҗатының башка төрләре, мәсәлән, җырлар, табышмаклар, әйтемнәрнең кайберләредәй, дәфтәрдән дәфтәргә күчерелеп алыну юлы белән дә сакланып калган.

Бәетләрнең бер ишләре, аерым бер кеше тарафыннан иҗат ителеп, халык теленә кереп киткән булса, кайберләре бөтен бер коллектив катнашы белән дә чыгарылган. Моның шулай икәнлеген күрү өчен сугыш хәлләрен тасвирлауга багышланган бәетләрдә күрергә мөмкин. XIX йөздә иҗат ителгән “Рус-төрек сугышы”, “Рус-япон сугышы”, “Беренче Бөтендөнья сугышы”һ.б. бәетләрне атарга була. “Рус -француз сугышы бәете”нең бер вариантында:

Дүрт –биш кердек сугышка, каннар билдән актылар,
Сугышларны бетергәч, безгә медаль тактылар,[6] -диелә.

Бәетләрне сугышларда яки башка тарихи вакыйгаларда катнашкан әнә шундый кешеләр генә чыгарганмы? Юк. Шул ук солдат бәетләренең кайберләре
тылда калган кешеләр тарафыннан да иҗат ителгәннәр.

Германия ачты сугыш көтмәгәндә,
Тату тору договоры бетмәгәндә.
Фронтларга чыгып китте ирләребез,
Озата бардык, яшькә тулы күзләребез,[7] -диелә “Германия сугыш ачты көтмәгәндә” бәетендә.

Шулай итеп, элек бәетләрне эшчеләр һәм крестьяннар, байлар һәм ярлылар, солдатлар, мәдрәсә шәкертләре, ягъни барлык катлам кешеләре дә катнашкан.

**Бәет башламнары**

Тарихи бәетләрнең иң зур күпчелеге “бисмиллаһи”сыз гына башланып китә. Мисал өчен Н.Ф.Катановның “Казан татарларының тарихи җырлары” исемле җыентыгына урнаштырылган бәетләрне алып карарга мөмкин. Анда кертелгән борынгы биш бәетнең барысы да “бисмиллаһи”сыз гына башланып китә. Татар халкының иң борынгы бәетләреннән “Сак-Сок”, “Хан кызы”,”Җиде кыз”, “Пугачев бәете”кебек әсәрләр дә бернинди керешсез иҗат ителгәннәр. Мәсәлән, “Тәзкия матур бәете”нең беренчесеннән өзек:

Тәзкия матур үсеп җитте, зифа иде буйлары,
Комсомолга керергә иде аның уйлары[8], - дип башлана.

Бәетләрнең башында вакыйганың елын-вакытын күрсәтү мәсьәләсенә килик. Әйе, бу – безнең күп кенә бәетләребез өчен хас бер күренеш. Мәсәлән, “Урта Тигәнәле бәете”, “Ышна бәете”, “Мәгъри кыз бәете”, “Себер киткән Гали бәете”, “Комсомолец Рәхи бәете”һ.б.:

Бер мең дә тугыз йөз дә утыз алтынчы елларда,

[6] Татар халык иҗаты: Хрестоматия. - Казан: Мәгариф, 2004, 354 нче бит
[7] Татар халык иҗаты: Хрестоматия. - Казан: Мәгариф, 2004, 444 нче бит
[8] Татар халык иҗаты: Хрестоматия. - Казан: Мәгариф, 2004, 418 нче бит

Башларырымны ашадылар кышкы салкын буранда,[9] - дип башланып китә “Комсомолец Рәхи бәете”.

Димәк, бәетләр “Бисмиллаһи вә биллаһи, җитте корбан гаете, без әйтиек, сез тыңлагыз...” кебек сүзләр белән башланып китә яки бәеттә тасвирланган вакыйганың елы, ае, урыны күрсәтелә.

**Бәетләрне өйрәнү мәсьәләсе**

Җыелу, басылу тарихларына килгәндә, бәетләр, Х.Бәдигый, Г.Толымбай, Х.Ярми, Ф.Әхмәтова, Р.Ягъфәров, А.Садыйковалар тырышлыгы белән чыгарыла.

Бәетләрне туплау һәм аларны фәнни өйрәнү өлкәсендә күп хезмәт куйган Г.Толымбай, бәетләрнең язма әдәбиятка якын торулары мәсьәләсенә тукталып, болай ди: “Бәетләрнең ничек таралуларын, саклануларын тикшереп карасак, аларның язма белән нык бәйле булуларын беләбез. Мәктәп-мәдрәсә шәкертләренең заманында бәет дәфтәрләре тотулары, ул чагында шәкертләрнең “әдәби көтепханәсе” шул бәетләр байлыгы белән үлчәнүе, шул шәкертләрнең үк бәет әйтеп йөрүләре шуны раслап торалар”.

Һичшиксез, аерым бәетләрнең язма хәлендә булулары яки дәфтәрдән дәфтәргә күчерелүләре аларның югалмыйча саклануларына һәм халык арасында таралуларына ярдәм иткән. Алар, халык авыз иҗатының башка төрләре кебек үк, аерым кешеләр – бәетчеләр тарафыннан такмак рәвешендә әйтелеп,яки һәрберсе үзенә махсус көйләнеп, телдән телгә күчү юлы белән дә таралганнар һәм шул юл белән дә сакланганнар.

Г.Тукай үз халкының талант иясе булуын һәм аның авыз иҗаты әсәрләрен иҗат итәргә сәләтле икәнлеген күрсәтергә теләп: “Чү, аз гына бер нәрсә шылт иттеме, инде аның турында иртәгә урамга бәетләр чыга”, ди. Менә шул рәвешчә, халык арасында, гомумән, халык тормышын яктырту ягыннан әһәмиятле һәм тирән эчтәлекле бәетләр иҗат ителү белән берлектә, алда әйткәнебезчә, тормышта була торган һәртөрле хосусый вакыйгалар һәм аерым трагик хәлләргә карата да (суга бату, мунчада ис тиеп үлү, атка тапталу һ.б. ) күп кенә бәетләр чыгарыла. Аерым бер кешенең бәхетсезлеккә очравы уңае белән кайгы белдерү рәвешендә иҗат ителгән бу төр бәетләр күп вакытта шул вакыйга булган авылның үзендә яки бәхетсезлеккә очраган кешенең туганнары, якыннары кулында гына сакланып калучан була.

Бәетләрнең аерым жанр буларак туу тарихы турындагы мәсьәләнең хәзерге көнгә хәтле махсус рәвештә тикшерелгәне, бу мәсьәләдә нинди дә булса ачык бер фикер әйтелгәне юк. Бездә борынгы чорны чагылдырган әдәби мирас, тарихи елъязмалар һәм истәлекләр тиешенчә сакланып кала алмаган һәм сакланып килгән хәтлесе дә кирәгенчә тупланмаган. Борынгы әдәби байлыгыбызның әле дә булса ныклап һәм һәрьяклап өйрәнелмәве язма әдәбиятның башлангыч нигезе булган халык иҗаты тарихын өйрәнүне дә кыенлаштыра. Шуңа күрә бәетләр турында да берьюлы тулы һәм төгәл бер фикер әйтүе кыен.

Ш.Мәрҗани Болгар чорында “Шәһәре Болгар газыйлары” һәм “Нәүруз” бәетләренең булуы турында ачык итеп әйтә. Бу бәетләрдән “Нәүруз бәете” безгә Урта Азиядән, башлыча таҗик халкыннан, килеп кергән булырга тиеш. Татар телендә аның бик күп вариантлары (күбесенчә, мәдрәсәләрдә) иҗат ителә.

Н.Ф.Катанов җыентыгында китерелгән “Казан бәете” белән “Мөхәммәт Әмин бәете”, Болгар чоры вакыйгаларын сурәтләү белән башланып китүләренә дә карамастан (Болгарның җимерелүе, Казан шәһәренең салынуы), “Мөхәммәт Әмин бәете” XYI йөзнең башларында, ә “Казан бәете” аннан соңгы чорда иҗат ителгән булса кирәк.

“Мөхәммәт Әмин” бәетеннән өзек китереп үтик.

Чыкты һиҗрәттән җиде йөз илледә;
Төште галәмгә хараплык зилзилә;
Үзе аксак, акылы ахмак, фетнәдә
Золымы изһар кыйлды һәр җирә.
Ни җавап бирер ходай каршында ул,
Сурса алла мәддәт вә гыйкаб белән?

[9] Татар халык иҗаты: Хрестоматия. - Казан: Мәгариф, 2004, 415 нче бит

Я илаһи, әйлә ул бәндәңне син,
Ахирәттә залим вә җаһил белән.[10]

Шулай итеп, бәетләр, Х.Бәдигый, Г.Толымбай, Х.Ярми, Ф.Әхмәтова, Р.Ягъфәров, А.Садыйковалар тарафыннан җыела һәм өйрәнелә.

**Бәетләрнең тематика ягыннан төрләре**

Бәетләрне халык тормышының сәнгати елъязмасы дип атарга мөмкин. Бәетләрнең бер зур тематик төркемен гади халыкның патша заманындагы коточкыч авыр көндәлек тормышын сурәтләгән әсәрләр тәшкил итә. Авыр хәлдә яшәгән крестьяннар патша чиновникларына каршы баш күтәрәләр, ләкин аяусыз бастырылып, гади халык каты җәзага тартыла: Себергә җибәрелә, солдатлар тарафыннан кыйнап үтерелә. “Урта Тигәнәле бәете” - әнә шундый классик әсәр.

Халык бәетләренең бер өлешен хатын-кызларның трагик язмышына багышланган әсәрләр алып тора. Бу бәетләрдә асрауларның, чит-ят илләргә сатып җибәрелгән, тормышта әледән-әле кабатланып торган шәхси фаҗигаләргә юлыккан (“Суга баткан Гайшә”, “Зөлхәбирә” бәетләре) яшь хатын-кызларның ачы язмышы, бәхетсезлеге, трагедиясе чагылыш таба.

Гражданнар сугышына багышланган бәетләрдә шәхесләрнең фаҗигасе үзәктә тора (“Үтерелгән Гали”, һ.б.). Аларда конфликт фаҗига аша чишелә.

Бөек Ватан сугышы елларындагы бәетләрне ике зур төркемгә бүлергә мөмкин. Беренчесендә ил тормышы, сугыш вакыйгалары белән бәйләнгән иҗтимагый эчтәлеккә ия бәетләр керә (“Мәскәүне саклау бәете”, һ.б.). Икенчесенә лирик бәетләр керә: “Салих улым”, “Батыр егет”, һ.б. Бәетләрдә кешеләренең, солдатларның, балаларын югалткан аналарның тирән кичерешләре гәүдәләнә. Бәетләр турында сөйләгәндә, тагын бер үзенчәлекле күренешне атап үтәргә кирәк. Татар халык иҗатында бәетләрнең берничә гасырга сузылган җитди традицияләре бар. Үзләренең яшәү дәверендә алар һәрвакыт язма мәдәният белән тыгыз бәйләнештә яшиләр. Күрәсең, әнә шундый традицияләр йогынтысында халыкның бәетләр иҗат итүдән туктатаны юк. Бәетләрнең хәзер иҗат ителә торганнарының зур өлеше шәхси фаҗигаләр белән бәйләнгән. Ә алар көн саен диярлек әле анда, әле монда кабатланып кына торалар. Бүгенге көндә дә мондый бәетләрне халык актив иҗат итә.

Димәк, бәетләрдә халыкның үсеш юлындагы тарихи вакыйгалар, көнкүрешендәге төрле хәлләр төрле яктылыкта чагыла килә.

**Бәетче Әсхадуллина Вәсилә иҗаты.**

Кукмара районы Ядегәр авылында да әнә шундый халык моң-зарының сагында торучы яши. Ул - 1947 нче елның 25 нче гыйнварында Починок Шәмәрдән авылында туган Асхадуллина Вәсилә Нурмөхәммәд кызы. Вәсилә апа гомерен үзенең туган якларына багышлаган, һәрчак шат, җырлап, гармун уйнап , мәҗлес күрке булып, бәетләр иҗат итеп яшәгән кеше (язманың кушымта өлешендә 8 бәете китерелә). Аның бәетләрендә сурәтләнгән кешеләр - төрле фаҗигаләргә юлыгып, вакытсыз дөньядан китүчеләр. Вәсилә апа иҗат иткән бәетләр шәхси фаҗигаләргә багышланса да, төрләргә аерырга мөмкин: эчүчелек белән бәйле, авариягә очрау, авыру аркасында.

Спиртлы эчемлек куллану үлемгә китергән, ”Сәлимгәрәй бәете”ндә фаҗига аркылы ятим калган малайларына, дусларына гыйбрәт булырлык сүзләр язылган:

Бергә эшләгән дусларым, эчәргә өндәдегез.
Бәлки хәзер үкенә- үкенә, үтәдер кәннәрегез.
Үкенегез! Эчмәгез сез, бетсен хәзер ялгышлар.
Сез эчсәгез, сезне көтә, шушындый ук язмышлар.

Хәзерге фән-техника заманасында яшәп, тормышыбызны күпкә җиңеләйтсәк тә, алар әле безнең якыннарыбызны фаҗигага юлыктыручы да. Рәкыйп һәм Кәримулла улы Мөхлисуллага багышланган бәетләрдә Вәсилә апа техниканы җан кыючы буларак сурәтли:

Бисмиллаһи диеп башлыйм

[10] Татар халык иҗаты: Хрестоматия. - Казан: Мәгариф, 2004, 294 нче бит

Бәетемнең башларын.
Комбайннарга кысылды
Минем газиз башларым.(“Рәкыйп бәете”)
Бисмиллаһи диеп куям
Бәетемнең башына.
Тиз йөрешле яшел поезд
Җитте минем башыма.(“Кәримулла улы Мөхлисулла бәете”)

Авыруның яше дә, карты да бер үк, үлемнең генә яше юк, диләр. Кайчагында ниндидер чир аркасында вакытсызрак тоелган үлем җир йөзендә бәхетсез ятимнәр дә калдыра шул. “Рәшидә бәете”, “Сөембикә бәете”, “Һадиев Габделбәр бәет”ләре - әнә шундый күңелсез, җанны тетрәндерерлек вакыйгаларның чагылышы. Аларда бу болгавыр заманның авырлыгы да, ятимнәр өлешенә төшкән фаҗига дә чаң авазы булып яңгырый.

Атасыз да, анасыз да
Калдыгыз сез,балалар.
Шушы ятим балаларны
Кемнәр хәзер карарлар, -дип борчыла ана “ Рәшидә бәете”ндә.
Дөнья камытын киясең
Яшьләй генә син үзең.
Иярмә, улым, начарларга
Тыңла, олылар сүзен.(“Сөембикә бәете”)
Мескеннәрем, хәзер мин дә китәм,
Каласыз сез бүген дөм ятим.
Аллаһ безгә менә шулай кушкан
Каршы килеп булмый, нишләтим.(“Һадиев Габделбәр бәете”)

Татар халкы үз фольклорында көлке әсәрләр тудыруга элек- электән яратып караган, аңа зур әһәмият биргән. “Аючылар” бәетенең көлкеле вариантлары, халык юморына бай “Кашык”, “Пести”, “Уңмаган килен”, “Чәй бәете” һ.б.ш. халык поэзиясен баетып, бизәп торганнар. Вәсилә апа да татар милләтенең лаеклы вәкиле буларак, әлеге темадан читләшмәгән. Үзенең “Мич бәете”ндә хәзерге рәхәт, уңайлы тормышның мичкә нинди “хәсрәтләр китерүен” шаярып көлү аша чагылдыра.

Дәрәҗәле үткән көннәрем,
Онытa алмыйм, гел дә уемда.
Хәзер инде ап-ак чеби генә,
Үстерәләр минем куенымда.

Бәет – татар эпосы. Гасырлар дәвамында бәет, илаһи бәет, бәет- мөнәҗәт, касыйдә кебек исемнәр белән аталып, халык йөрәгендә, дәфтәр битләрендә, китап читләрендә яшәүче әсәрләр. Татар халкының үзе шикелле борынгы заманнарда ук туган, төрле жанрлар белән аралашып үскән, яшәүдән туктамаган милли жанр ул. Фәнни-эзләнү эшен тәмамлагач, түбәндәге нәтиҗәләр ясалды:

1.Бәетләрне иҗат итүдә халыкның барлык катлау вәкилләре: эшчеләр һәм крестьяннар, байлар һәм ярлылар, солдатлар, укымышлылар, ягъни мәдрәсә шәкертләре дә катнашкан.

2. Бәетләр “ Бисмиллаһи вә биллаһи, җитте корбан гаете, без әйтиек, сез тыңлагыз...” кебек сүзләр белән башлана яки бәеттә тасвирланган вакыйганың елы, ае, урыны күрсәтелә. Тарихи бәетләрнең иң зур күпчелеге “бисмиллаһи”сыз гына башланып китә.

3. Җыелу, басылу тарихларына килгәндә, бәетләр, Х.Бәдигый, Г.Толымбай, Х.Ярми, Ф.Әхмәтова, Р.Ягъфәров, М.Бакиров һ.б.тырышлыгы белән чыгарыла.

4. Бәетләрдә халыкның үсеш юлындагы тарихи вакыйгалар, көнкүрешендәге төрле хәлләр туктаусыз рәвештә һәм төрле яктылыкта чагыла килә.

5. Бәетче В.М.Әсхадуллинаның бәетләрендә сурәтләнгән кешеләр - төрле фаҗигаләргә юлыгып, вакытсыз дөньядан китүчеләр. Алар шәхси фаҗигаләргә багышланса да, төрләргә аерыла: эчүчелек белән бәйле, авариягә очрау, авыру аркасында.

6. Авылыбызның яшәеше, көнкүреше, кешеләренең хис-кичерешләре турында мәгълүмат бирүдә, туган як тарихын өйрәнүдә шактый әһәмияткә ия ул.

Халкыбыз зәвыгының яшәүгә омтылыш идеалын гамәлгә ашыруда бәетләр кешенең чиксез хыялы белән якты дөнья тормышын данлый, аңа гимн булып яңгырый. Теленнән, диненнән язмас өчен кайчак үз иленнән аерылырга мәҗбүр халыкның читтәге яшәү - көнитешен сурәтләүче тормыш мәктәбе дә ул. Дуслар, туганнар белән тату, күршеләр белән килешеп, дошманы белән ызгышмый яшәгән бөек халык дипломатиясен дә күрсәтә, шуңа күрә яши, тереклеген дәвам итәр татар халык эпосы - бәет.

*Файдаланган әдәбият:*

1.Әхмәтова- Урманче Ф.В. "Татар эпосы. Бәетләр" .- Казан: Раннур, 2001.
2. Бакиров М.Х. Татар фольклоры. - Казан: Мәгариф, 2008.
3. Исламов Ф.Ф. "Мәктәптә халык авыз иҗаты әсәрләрен өйрәнү". - Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1988.
4. Урманчеев Ф.И. Халык авыз иҗаты. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1974.
5. Хәбибуллина З.Н. , Фәрдиева Х.Г. 5-11 нче сыйныфларда татар теле һәм әдәбиятыннан дәрестән тыш эшләр. - Казан, "Мәгариф" нәшрияты, 2000.
6. Ярми Х. "Татар халкының поэтик иҗаты". - Казан , Татарстан китап нәшрияты, 1967.
7. Бәетләр, мөнәҗәтләр. - Казан, "Мәгариф" нәшрияты, 2000.
8. Татар халык иҗаты.- Казан,"Мәгариф"нәшрияты, 2004.
9. Татар халык иҗаты.Бәетләр. - Казан," Татарстан китап нәшрияты", 1983.
10. Әсхадуллина Вәсилә апаның шәхси язмалары

## АЙГӨЛ ӘХМӘТГАЛИЕВАНЫҢ "КҮЗ НУРЛАРЫМ" ДРАМАТИК ХИКӘЯСЕНЕҢ ТӘРБИЯВИ ӘҺӘМИЯТЕ

*Бәширов Рәзил Рамил улы, МАГБУ"Казан шәһәре Советлар Союзы Герое С.Ә. Әхтәмов исемендәге 121 нче лицей"ның 10нчы сыйныфы укучысы,*
*Фәнни җитәкче: Сәйфуллина Гөлшат Илдус кызы*

Кешелек җәмгыятендә ата-ана һәм бала, тәрбия, рухи һәм матди байлык мәсьәләләре һәрвакыт актуаль булган. Яшәү мәгънәсе, тормыш фәлсәфәсе турында да уйланмый калган кеше юктыр, мөгаен. Шагыйрьләр һәм язучылар бу проблемаларга һәм сорауларга аеруча игътибарлы. Тормышта очраган хәлләргә бәя, аларны чишү юллары, шул мәсьәләләргә карата үз фикерләрен алар әсәрләре аша белдерәләр. Гаиләгә бәйле рәвештә әхлаксызлык, кешелексезлек, миһербансызлык, ата-ананы хөрмәт итмәү, балаларны ятим калдыру проблемалары да яктыртылып килә.

Күптән түгел Айгөл Әхмәтгалиеваның "Күз нурларым" драматик хикәясенең сәхнәдән куелышын карарга туры килде. Югарыда телгә алынган мәсьәләләр бу әсәрдә бигрәк тә кискен чагылыш таба. Соңгы елларда, икътисадый тормышта капитализм мөнәсәбәтләре урнаша бару нәтиҗәсендә, байлык артыннан куу кешеләрнең төп максаты булып әверелә башлау күренеше дә һәм аның тискәре нәтиҗәләре дә тәэсирле күрсәтелгән.

Әлеге спектакль күпләрнең, шул исәптән минем дә күңелемне урыныннан кузгатты, күптөрле фикерләр уятты. Әсәрнең язмача варианты белән танышу һәм анда күтәрелгән әдәп-әхлак мәсьәләләрен тагын бер кат күздән кичереп анализлау теләге барлыкка килде.

Югарыда әйтелгәннәр барысы да мәңгелек темалар аша бүгенге көн үзәгендә торган мәсьәләләрне ачып биргән "Күз нурларым" драматик хикәясенең тәрбияви әһәмияте буенча язылган фәнни-гамәли тикшеренү эшебезнең ***актуальлеген*** күрсәтә.

***Тикшерүнең объекты*** – Айгөл Әхмәтгалиеваның бүгенге көн язмышлары буенча язылган "Күз нурларым" драматик хикәясе.

***Өйрәнү предметы*** итеп шул әсәрдә күтәрелгән әдәп-әхлак, гаилә проблемалары, һәм әсәрнең тәрбияви әһәмияте үзенчәлекләре алынды.

***Фәнни-тикшеренү эшенең максаты***: Айгөл Әхмәтгалиеваның "Күз нурларым" драматик хикәясенең тәрбияви әһәмиятен ачыклау. Әлеге максатка ирешү юлында түбәндәге ***бурычлар*** куелды:

- Айгөл Әхмәтгалиеваның тормыш һәм иҗат юлы белән танышу, аның белән булган интервьюларны уку;
- "Күз нурларым" спектаклен карау һәм әсәрне уку;
- әсәрне идея-проблема ягыннан анализлау;
- тәрбияви максатны тормышка ашыруга хезмәт иткән алымнарны, тел чараларын билгеләү;
- әсәрнең әһәмиятен һәм әдәбияттагы ролен ачыклау.

Әлеге максат һәм бурычларга ирешү өчен тасвирлау, чагыштыру, анализлау ***алымнары*** һәм ***методлары*** кулланылды.

***Теманың өйрәнелү дәрәҗәсе*** һәм хезмәтебезнең ***фәнни яңалыгы.*** Айгөл Әхмәтгалиеваның яңа әсәрләре даими рәвештә газета-журналларда басылып килә, нәшер ителгән китаплары да бар. Әмма "Күз нурларым" әсәренең басма варианты әле укучыларга тәкъдим ителмәгән, бары тик авторның үзендә генә бар. Ә сәхнәләштерелгән вариантын Раил Мөхетдинов җитәкчелегендәге "Өмет" театры башкаруында күрергә мөмкин булды. Шунлыктан, әлеге әсәр буенча әле тәнкыйть мәкаләләре һәм башка фикерләр юк. Бу факт эшебезнең фәнни яңалыгын күрсәтә.

*Геройлар сөйләмендә кулланылган мәкальләрнең мәгънәләре һәм әсәрдәге роле*

"Амбар төбендә икмәк бар, картлар сүзендә хикмәт бар", - дигәннәр борынгылар. Чыннан да, олылар сөйләмендә тормыш тәҗрибәсе, акыл чагылыш таба. Аларның кайберләре телдән-телгә күчеп тә кулланыла. Борынгы әби-бабаларыбызның әнә шундый тапкыр сүзләре телебездә мәкаль һәм әйтемнәр буларак формалашып калган.

"Мәкаль – тормыштагы төрле гыйбрәтле күренешләрне гомумиләштереп, тапкыр әйтелгән тәгъбир, фраза"[11], диелә татар теленең аңлатмалы сүзлегендә. Ул тирән мәгънәне эченә ала һәм сөйләшкәндә сүзгә ямь һәм куәт бирә. Шуңа күрә, мөгаен "Әйтем — сүзнең бизәге, мәкаль — сүзнең җиләге", дигәннәр.

Айгөл Әхмәтгалиеваның "Күз нурларым" әсәрендә мәкаль һәм әйтемнәр шактый күп кулланыла. Ләкин геройлар сөйләмендә, аеруча Ана образы телендә кулланылган бу сүзләр әсәрнең сәнгатьлелеген бозмый, тормышчанлыгына зыян китерми. Алар үз урынында бик отышлы кертелгән һәм тәрбияви максатны тормышка ашыруда зур роль башкаралар.

Ана әйткән хикмәтле сүзләрнең күбесе бала тәрбияләү, гаиләдәге мөнәсәбәтләргә бәйле. Тормыш тәҗрибәсе туплаган бу Ана ир хатыны булган үз кызына бәхетле гаилә, тәрбияле бала серләрен төшендерергә тырыша.

"*Ата-ананың бөтен куанычы – балалар бәхете*", ди Ана, ә балалар бәхетле булсын өчен әти-әниләре янында, тигез гаиләдә үсү мөһим. Шуңа күрә дә оныгына бәхет теләгәндә ул "*Ата-аналы, алтын канатлы*" булсын ди.

Гаиләдә бала карау, аны тәрбияләү күбесенчә хатын-кызга эләгә, Ана моны хатын-кызның төп эше дип атый.

Балаларны тәрбияләү турында сүз чыкканда ул тагын "*Бала алдында дилбегәне берегез уңга, икенчегез сулга тартмагыз берүк"*, - ди ул, чөнки ата-ана икесе ике төрле өйрәтеп, берсе әрләгәндә икенчесе баланы яклап чыкса, әти-әнинең авторитеты төшә, зурая төшкәч бала әтисен дә, әнисен дә санга сукмый башлый. Ә менә аннан соң гаиләдә аңлашылмаучанлыклар, җитди проблемалар да барлыкка килергә мөмкин. Бу турыда Ана *"Бала тездә чакта сөйдерә, ә менә тездән төшкәч көйдерә шул ул"*, - ди. Мондый хәлләр килеп чыкмасын өчен балаларга баштан ук игътибар бирергә, аларга наз һәм җылылыкны да

[11] Татар теленең аңлатмалы сүзлеге / Төз. З. Мифтахов. – Зәй: Шәхси китап нәшрияты, 2012.

кызганмаска, ярамаганнан тыярга да кирәк. Эш белән онытылып, балаларны икенче планга калдыру дөрес түгел. Ана фикеренчә, дөьяның койрыгын тотып булмый, “*шәм кебек сызыла да төшә шул гомеркәйләр*”, ә “*талны яшь чагында бөгеп калсаң гына...*”.

Ана боларны бер дә юкка гына әйтми. Аның кызы, ягъни Хатын һәм кияве, ягъни Ир акча эшлибез дигән булып, балалары белән бергә булырга да вакыт тапмый башлыйлар. “Минем өйдә каласым килә” дигән улларына һәм “Минем сезнең янда буласым килә, әнием”, дип бер атналык балалар бакчасына барырга теләмичә ялынган кызларына алар эшләренең күплеген сәбәп итеп куялар һәм нык ялгышалар.

Чыннан да, кеше бәхетле булсын өчен байлык кына җитми. Иң беренче чиратта, гаиләдә бер-береңә җылы мөнәсәбәт һәм ышаныч булырга тиеш. *“Икегез бер сүздә булсагыз, арагызга сүз дә, күз дә кермәс*”, - ди Ана. Аның сүзләре дөрес булып чыга, бер-берсен аңлап, саклап яшәгәндә ир һәм хатынның байлыклары булмаса да, үзләрен алар бәхетле хис итәләр. Хатын *“түшәмеңнән биегрәк сикереп булмый инде*”, дип, ә Ир “*Күңелең киң булса сыябыз*”, дип, кечкенә генә бүлмәдә дә гөрләшеп, матур яшиләр.

Баеп киткәч, Хатынның “*Бар почмак та түгәрәкләнсә, берәр җире генә кителә башламасын*”, дип куркуы дөреслеккә чыга. Алар чын гаилә бәхетен, гаилә җылысын мал-мөлкәткә, байлыкка алмаштыралар. Бар нәрсәләре дә җитеш булды дип уйлап ялгышалар, әкренләп бәхетләрен үзләре үк җимерәләр.

Күрәбез: Айгөл Әхмәтгалиеваның “Күз нурларым” драматик хикәясендә мәкальләр, дөрестән дә шактый күп кулланылган. Аларның шактые Ана образы тарафыннан, кайберләре Ир, Хатын образлары тарафыннан да әйттерелә. Бу мәкаль һәм әйтемнәрнең һәрберсе дә тирән мәгънәгә ия. Алар безне, ягъни әсәрне укучыларны һәм сәхнәләштерелгән вариантны караучы тамашачыларны гаиләдә бер-береңне аңлап яшәргә, бер-береңә игътибарлы булырга, гомерләрне файдалы итеп уздырырга өйрәтә. Автор шулай ук гомернең тиз үтүен, тормышта байлыкның беренче урында булмавын да хикмәтле сүзләр аша җиткерә.

*Яшәү мәгънәсе, бәхетле тормыш турында уйланулар аша күтәрелгән әдәп-әхлак мәсьәләләре*

Кеше дөньяга яшәр өчен туа. Ә ул күпме яшәргә, ничек яшәргә тиеш? Яшәүнең мәгънәсе нәрсәдә? Кеше гомере буе үзенең асылын аңларга омтыла, яшәүнең мәгънәсенә төшенергә тырыша. Һәм яши-яши андый җавап үзеннән-үзе табыла.

Әдәбиятта да бу темага зур игътибар бирәләр. Айгөл Әхмәтгалиеваның “Күз нурларым” драматик хикәясендәге геройлар да яши-яши шушы сорауга җавап табарга омтылалар. Аларның күбесе гомерләре буе бары тик акчага гына табынып, мал артыннан куып яшиләр, дөньда һәр нәрсә белән акча идарә итә дип уйлыйлар. Егет: *“ Бу дөньяның патшасы да, Алласы да - акча, акча, акча”,* - ди. Ә чынлыкта исә акча һәрвакытта да бәхеткә генә илтми. Акчага Дус менә ничек бәя бирә: *“Юк инде, җаныңны акчага саткансың икән, синең табынганың, сәҗдә кылганың – бары тик акча, акча, акча гына була ала, җанкисәгем. Ә акча ул – сине кол итә, үз кубызына теләгән көенә биетә. Аһ, ничек дәртле, ничек сихерле аның көе?! Елан кебек, телләреңне асылындыра-асылындыра биисең. Хәлең бетеп туктарга уйласаң да, ул көй сине мәрткә киткән җиреңнән кабат торгызып биетә”.*

Дөрестән дә, кешенең бәхете акчада гына түгел. Аннан күпкә югарырак кыйммәтләр дә бар. Байлыкта коенып яшәп тә, соңыннан үзен бәхетсез хис иткән Ханым Хатынга: “*Акчаның кулләрендә йөзеп яшим, баштарак, ай, ничек рәхәт иде. Тик соңыннан эчтән нидер кимерә башлады. Аннан сезне күрдем. Сез... шыр ялангач өйдә, иске шәлгә төренгән балаларыгызны үчтекиләп, бер-берегезнең күзенә генә карап, бәхет күлендә коенып яшәп ята идегез...”,* - ди. Димәк, ул чын бәхетнең тату гаилә, балалар сөю, яратып-яратылып яшәү икәненә төшенә һәм көнләшүдән Ир белән Хатынның да тормышларын боза.

Байлыкка омтылу, кешедән көнчеләнеп араларына керү, начарлык эшләү исә барысы да кешенең нәфсесенә бәйле. Әсәрдә акыллы киңәшләр бирүче, туры юл күрсәтүче образ буларак бирелгән Ана сүзләре аша бу бик ачык аңлашыла: *“Заманаы гына гаепләү дөрес микән, балам? Дөнья пычрак түгел, бәндәләрнең күңеле керле. Нәфес каралта йөрәкләрне, нәфес. Матурлык күрергә яратылган күзләрне дә, Ходайдан иңгән сүзләрне ишетергә дип*

*бирелгән колакларны да, иман белән мөлдерәмә булырга тиешле күңелләрне дә шул мәлгуньк каплап тора".*

Әсәрнең башка геройлары бу хакыйкатьне бик соң аңлыйлар. Уйлап карасаң, чыннан да, байлыкны кеше үзе белән мәңгелеккә алып китә алмый, яман чирләрдән, кайгы-хәсрәттән акча белән генә котылу мөмкин түгел. Димәк, яшәү мәгънәсен мал-мөлкәт белән бәйләп карау һич тә дөрес түгел. Дус: *"Яшәү мәгънәсе – үлем икән ләбаса. Теләсә кайсы мизгелдә якаңнан тотып алырга әзер Әҗәл агай икән. Дөнья белән акча түгел, Аллаһ идарә итә?! Барыбызның да юл ахыры бер нокта"*, - ди. Бу сүзләр аша үзеңнән соң эз калдырырлык итеп яшәргә кирәклеге аңлашыла. Байлык ул бер генә көнлек булырга да мөмкин, ә эшләгән яхшылык, изгелекләр онытылмый. Гомереңне матур итеп яшәү өчен акча артыннан куарга түгел, ә янәшәдәгеләреңне дә бәхетле итәргә омтылып, тирә-юньдәгеләргә булдыра алганча ярдәм итеп, бер-береңне аңлап яшәргә кирәк икән.

*"Ана"ның кеше тормышындагы урыны*

Әни – җир йөзендә иң кадерле, иң газиз кеше. Балага ана назы, ана җылысы бик кирәк. Әни кешенең игътибары җитмәгәндә бала тупас, кырыс булып үсә, башкаларга карата ышанычын югалта. Айгөл Әхмәтгалиева үзенең "Күз нурларым" әсәрендә, әнисе ташлап киткән Ханымны һәм әнкәсе янәшәсендә булып та, "әнисез үскән", ягъни ана назы күрмәгән Кыз образлары аша бу проблеманы бик ачык яктырта. Аларның үз-үзләрен тотышлары, характер сыйфатларында гына түгел, ә сөйләмнәрендә дә әниләрнең кеше тормышындагы, дөньяга караш, гомумән, шәхес формалашудагы роле чагылыш таба.

Ханым – Дусның хатыны, шулай да алар бер-берсе белән ирекле мөнәсәбәттә яшиләр, араларында хис юк. Ханымны иренең акча алып кайтып торуы канәгатьләндерә. Баштарак эче пошса да, соңыннан үз күңелен үзе күреп яши.

Тик кешенең күңел халәтен белеп бетереп булмый шул. Инде яшәү мәгънәсе турында уйлана башлап, ире аны таш бәгырьле, җансыз булуда гаепләгәч, Ханым ачылып китеп менә нәрсә ди: *"Бәгырь, имеш. Җан, имеш... Ул бәгырьнең ни сәбәпле таштан да катыракка әверелүен аңлыйсыңмыни син... Дөньяга туганчы ук бәгырьсезләрдән ярал да... Минем бит бит үз гомеремдә бер генә кешегә дә, бер генә тапкыр да әни дип эндәшеп караганым юк! Кем ул мине тудырган кеше, ни җаны белән үз сабыен язмыш кочагына ташлап калдырган? Нинди була ул әни төсе, әни исе, әни пешергән аш тәме – мин бит боларның барысыннан да мәхрүм идем... Мин дөньядагы иң олы бәхеттән мәхрүм үстем! Ишетәсеңме, мин әни җылысыннан мәхрүм идем! Үзем дә әни була алмадым... Минем үземә дә беркем дә, беркайчан да, бер генә тапкыр да әни дип дәшмәячәк... Ә син җан дисең, бәгырь дисең..."*

Ханымның сүзләреннән аермачык аңлашыла: бала ничә яшьтә генә булуга да карамастан, аңа ана назы, аны җылысы кирәк. Әнә шул газиз кеше сине тугач ук ташлап киткән икән, бөтен әйләнә-тирәдәгеләргә ачу, мәрхәмәтсезлек, мәкер барлыкка килүдә аның гаебе зур.

Хатын-кыз өчен әниле булу гына түгел, ә үзең әни булу да мөһим. Ханым бу бәхеттән дә мәхрүм ителә. Аның менә шундый хәйләкәр һәм астыртын булуына монысы да тәэсир иткән.

Әсәрдәге икенче бер персонажның – Кызның әтисе дә, әнисе дә бар. Әмма ул да әнисенә мәрхәмәтсез, тупас булып үсә. Ни өчен? Бу сорауга да әсәр ахырында җавап табабыз. Аны Кыз үзе үк әйтеп бирә:*"Ә мин бүген тагын балалар йортында булдым. Пустышкалар, пеленкалар, гөлҗимеш сироплары, памперслар илттем. Әти акчасына! Андагы балалар да минем кебек – алар да елмая-көлә белми (башын ия). Алар дөньяда әти һәм әни дигән затларның барлыгын да белми. Ә минем бит әтием дә, әнием дә бар!!!"*

Хатын Кызның сүзләрен куәтләп, тагын да җитдирәк, тәэсирлерәк, тирәнрәк итеп ана җылысы турында сөйли. Аның сүзләреннән кешенең шәхес буларак формалашуында, гомумән җәмгыятьтәге мөнәсәбәтләрнең нинди булында иң мөһим рольне башкаруы аңлашыла. Кызының шулай битараф, салкын характерлы булып үсүендә үзенең гаебе барлыгын таный ул һәм соңга калып аңлавына бик үкенә: *"Бу шәлне сиңа бирәм, кызым. Иске дип чыгарып ташлама берүк. Әбиеңнең дә, әзме-күпме минем дә җан җылысы сеңгән*

*аңа. Син инде җиткән кыз, беркөн килеп үзең дә әни булырсың. Почык борынлы нарасыеңны шушы шәлгә төреп тирбәткәндә, бернәрсәне гомерлеккә күңелеңә салып куйсаң икән, кызым: бу дөньяда ана җылысыннан да кайнаррак берни юк. Шул җылы җитмәгәндә балалар каты бәгырьлегә, җансызга әйләнә икән. Балалар гына түгел, бар дөньясы бозга әверелә икән... Кызганыч, мин үзем моны соңга калып аңладым. Бик соңга. Рәнҗемәгез миңа, күз нурларым...”*

Алда әйтелгәннәрне гомумиләштереп шуны әйтергә мөмкин: кеше өчен әни һәрвакыт кирәк. Кешенең шәхес буларак формалашуында аның роле бик зур. Ана назы, ана җылысы күрми үсүчеләрнең күбесе каты бәгырьле, кырыс, башкаларга шәфкать-миһербансыз булалар. Әниләре ташлап киткәннәрнең күңелендә ышаныч кими. Әсәрнең авторы Айгөл Әхмәтгалиева хатын-кызның төп миссиясе итеп бала тәрбияләүне күрсәтергә тели. Баланы матди яктан тәэмин итүгә караганда, аңа игътибарлы булу, тәрбияләү күпкә мөһимрәк. Автор фикеренчә, шул вакытта гына җәмгыятьтә дә явызлыклар азрак булачак.

Татарстан Республикасының журналистлар берлеге, Язучылар берлеге әгъзасы Айгөл Әхмәтгалиева иҗаты бик үзенчәлекле. Аларда бүгенге көннең иң катлаулы мәсьәләләре чагылыш таба. Геройлары да үзебезнең арадан алынган кебек чынбарлыкка бик якын торалар. Бу турыда язучы үзе әңгәмә вакытында болай ди: “Геройларны кайлардан табаммы? Кая барсам да, табыш белән кайтам мин. Табыш дигәнем – берәр язма яки хикәя өчен тема, геройлар инде. Казанга еш йөргәч, юлда кемгә дә булса “бәйләнми” калмыйм. Дөрес, бөтен сөйләгән сүзне дә кәгазь битенә төшереп булмый. Ниндидер мәгънә яки гыйбрәт, сабак “табылса” гына укучыга тәкъдим итәргә мөмкин”[12].

Айгөл Әхмәтгалиеваның без тикшерү объекты итеп алган “Күз нурларым” әсәре дә бик тормышчан. Автор үзе хикәя башында “бүгенге көн язмышлары” дип аңлатма биреп китә. Димәк, ул бүгенге тормышта булган реаль хәлләрне чагылдыра дип әйтергә дә мөмкин.

Язучы ата-ана һәм бала, матди һәм рухи байлыкка бәйле мәңгелек проблемаларны күтәреп чыга, яшәү мәгънәсе, бәхетнең асылы турында уйландыра. Әсәр тәрбияви яктан да зур әһәмияткә ия. Бу турыда гомумиләштереп, без түбәндәге нәтиҗәләрне ясый алабыз:

1. “Күз нурларым” әсәрендә мәкаль һәм әйтемнәр шактый күп кулланыла. Алар үз урынында бик отышлы кертелгән һәм тәрбияви максатны тормышка ашыруда зур роль башкаралар.

2. Мәкаль һәм әйтемнәрнең шактые Ана образы тарафыннан, кайберләре Ир, Хатын образлары авызыннан да әйттерелә. Ана әйткән хикмәтле сүзләрнең күбесе бала тәрбияләү, гаиләдәге мөнәсәбәтләргә бәйле. Аларда бәхетле гаилә, тәрбияле бала серләре чагыла, ягъни бер-береңне аңлап яшәргә, игътибарлы булырга, гомерләрне файдалы итеп уздырырга өйрәтә, шулай ук гомернең тиз үтүен, тормышта байлыкның беренче урында булмавын да җиткерә.

3. Хикәядәге тәрбияви максат геройларның яшәү мәгънәсе, бәхетле тормыш турындагы уйланулары аша да тормышка ашырыла. Кешенең бәхете акчада гына түгелеге, аннан күпкә югарырак кыйммәтләр барлыгы раслана. Гомереңне матур итеп яшәү өчен акча артыннан куарга түгел, ә янәшәдәгеләреңне дә бәхетле итәргә омтылып, тирә-юньдәгеләргә булдыра алганча ярдәм итеп, бер-береңне аңлап яшәргә кирәк икән.

4. Әсәрдә әдәп-әхлак мәсьәләләре Ана образы һәм хатын-кызның төп бурычы турындагы фикерләр аша да күтәрелә. Кешенең шәхес буларак формалашуында ананың роле бик зур. Ана назы, ана җылысы күрми үсүчеләрнең күбесе каты бәгырьле, кырыс, башкаларга шәфкать-миһербансыз булалар. Әниләре ташлап киткәннәрнең күңелендә ышаныч кими. Әсәрнең авторы Айгөл Әхмәтгалиева хатын-кызның төп миссиясе итеп бала тәрбияләүне күрсәтә.

*Кулланылган әдәбият:*

---

[12] Йосыпова Л. Айгөл Әхмәтгалиева белән интервью / Ирек мәйданы. – 7 апрель, 2016.

1. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге / Төз. З. Мифтахов. – Зәй: Шәхси китап нәшрияты, 2012.
2. Йосыпова Л. Айгөл Әхмәтгалиева белән интервью / Ирек мәйданы. – 7 апрель, 2016.
3. Әхмәтгалиева А. Күз нурларым (әсәрнең электрон варианты автордан алынды)

## ШӘХСИ ХАТЛАР: ТӨРЛӘРЕ ҺӘМ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

*Вәлиуллина Азалия Нәзир кызы, 7 нче сыйныф укучысы*
*Фәнни җитәкче: Мөбарәкшин Марат Фәрхәт улы,*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы,*
*Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы*
*Курсабаш төп гомумбелем бирү мәктәбе,*

**Теманың актуальлеге**. Эпистоляр стиль – функциональ стильләрнең бер төре. Ул башка стильләрдән үзенең кулланылыш дәрәҗәсе, вазыйфасы, белән аерылып тора. Эпистоляр сүзе “эпистола” сүзеннән алынган һәм “хат, юллама” мәгънәләрен белдерә.

Эпистоляр стильнең бик бай тарихы бар. Ул борынгы чорларда ук кешеләр арасында киң кулланылган. Бу стиль хатлар жанрын өйрәнә. Гомумән, хат кешеләр арасында язма аралашу процессын барлыкка китергән, коммуникатив функцияне башкарган.

Вакытлар үтү белән, җәмгыятьтә барган төрле процесслар нәтиҗәсендә, аның кулланылыш даирәсе үзгәрә һәм язу манерасы да үзгәреш кичерә. Инде XIX гасырларда ук хат язуга карата галимнәр тарафыннан кызыксыну башлана һәм эпистоляр стильгә кагылышлы хезмәтләр барлыкка килә, хат язуга карата билгеле бер таләпләр куела һәм, нәтиҗәдә, хат шаблонга нигезләнеп языла башлый.

Җәмгыятьтә барган фәнни-техник прогресс хатларга да тәэсир итмичә калмый. Шул сәбәпле хат язуның яңа формалары барлыкка килә. Мәсәлән, гадәти хат язуны электрон формадагы хатлар алыштыра. Ләкин шулай да гадәти формада хат язу юкка ук чыгып бетми.

Бүгенге көн – коммуникация, техника заманы. Кешеләр бер-берләре бик тыгыз бәйләнештә торалар. Әлеге мөнәсәбәтләрне булдыру өчен, билгеле бер аралашу чарасы кирәк. Шуңа күрә хатларның бүгенге көндә әһәмияте, кулланылыш даирәсе бермә-бер артты. Хат кешеләр арасында тыгыз элемтә урнаштырды, шуңа күрә алардан башка бүгенге җәмгыятьтәге тормышны күз алдына да китерүе кыен. Шулай итеп, алар, безнең җәмгыятебезгә үтеп кереп, ныгып калдылар.

Тел белемендә хатларны төп ике төргә бүлеп карыйлар: шәхси һәм рәсми хатлар. Шәхси хатларны өйрәнү бүген бик тә актуаль мәсьәлә булып санала, чөнки алар, аралашуның үзенчәлекле формасы буларак, XX гасырда гына тикшерелә башладылар. Шулай итеп, фәнни хезмәтебезнең төп өйрәнү объекты – шәхси хатлар, ә өйрәнү предметы булып аларга хас үзенчәлекләр тора.

Фәнни хезмәтебезнең төп **максаты** – шәхси хатларга хас үзенчәлекләрне ачыклау. Шул максатка ирешү юлында түбәндәге **бурычлар** куелды:

1) шәхси хатларның төрләрен аерып чыгару;
2) аларның теоретик нигезен булдыру, төзелешен ачыклау;
3) шәхси хатларның үсеш-үзгәрешен билгеләү;
4) алардагы стилистик, лингвистик үзенчәлекләрне аерып чыгару;
5) бу үзенчәлекләрне күренекле әдипләрнең хат үрнәгендә күрсәтү.

**Чыганаклар** буларак, күренекле әдипләребезнең хат үрнәкләре алынды. Бигрәк тә Фатих Кәрим, Габдулла Тукай, Фатих Әмирхан хатларына нигезләнеп тикшерелде.

**Тема өйрәнелүнең торышы.** Шәхси хатлар күпмедер дәрәҗәдә өйрәнелгән. Аны аерым өйрәнү каралмаса да, функциональ стилистикага кертеп караганнар. Әлбәттә, рус галимнәреннән беренче булып, В.В. Виноградов рус стилистикасын өйрәнүгә бәйле хатларга зур игътибар бирә. Татар галимнәреннән Х.Р. Курбатов, В.Х. Хаков хезмәтләрен атап үтәргә кирәк. Гомумән алганда, аларның фикерләре хатларга карата бердәй, зур аерымлыклар күзәтелми.

Бүгенге көндә дә шәхси хатларны өйрәнү, булган мирасны барлау эше алып барыла. Хәзергә көндә аларны гомуми өйрәнү күзәтелмәсә дә, аларның аерым бер ягы тикшерелә. Бу нисбәттән бик күп диссертацияләр, авторефератлар язылган. Хатларны өйрәнү эше тукталып тормый. Фәнни хезмәтебезнең **методологик нигезен** В.Х. Хаков, Х.Р. Курбатов, А.И. Әүһәдиева хезмәтләре тәшкил итә һәм нәкъ менә аларның фикерләренә нигезләнеп ачыклау төп урынны алып тора. Шулай ук рус галимнәрнең мәкаләләре, авторефератлары, сүзлекләр дә файдаланылды.

Фәнни хезмәтебезне язу барышында төрле **методлар һәм алымнар** кулланылды: хатларны тикшерү, чагыштыру, индуктив, дедуктив. Мәсәлән, шәхси хатларга хас үзенчәлекләр чагыштырылды. Үзенчәлекләрне таркату аша, гомуми анализ ясалды. Шулай ук охшаш билгеләрне бергә туплап, гомуми фикер расланылды. Хатларны өйрәнүдә тарихи аспектка зур игътибар ителде, чөнки төрле чорда язылган хатлар бер-берләреннән бик тә нык аерылалар.

**Хезмәтнең теоретик һәм практик әһәмияте** дә зур урынны алып тора, чөнки әлеге хезмәтебездә хатларның теоретик нигезе һәм үзенчәлекләре чагылыш таба һәм шәхси хатларга хас төп үзенчәлекләр күрсәтелә. Фәнни хезмәтебезне башка төрле фәнни эшләр башкарганда кулланырга мөмкин.

**Хезмәтнең төзелеше**. Фәнни хезмәтебез төп ике бүлектән тора. Беренче бүлектә шәхси хатларның төрләре карала. Аларны ачыклау максатыннан, әдипләребезнең хат ядкарьләреннән үрнәкләр китерелә.

Икенче бүлектә хатларның һәрбер аерым төре киңрәк аспектта карала. Аларга хас лингвистик, стилистик үзенчәлекләр аерып күрсәтелә. Бу билгеләр әдипләрнең хат үрнәкләре белән ныгытыла.

Шәхси хатлар бик күп төрле функция үтиләр. Алар ике субъект арасында элемтә урнаштыралар. Шәхси хатлар аша без бик күп әйберләрне, күренешләрне танып беләбез, чор турында мәгълүмат туплыйбыз. Хатлар аралашу чарасын башкаралар. Аларны өйрәнү, барлау, туплау әһәмиятле, чөнки алар безнең язма һәм сөйләмә тарихыбызны яктырталар. Хат ул – безнең халкыбызның тарихи, мәдәни ядкаре. Шуңа күрә аларны өйрәнү, тикшерү бүген бик тә мөһим мәсьәлә булып кала бирә.

**Шәхси хатларның төрләре**

Шәхси хат – эпистоляр стильнең иң үзенчәлекле төре булып санала. Аларга типик элементлар хас: эндәшү, дата, имза кую, адресаттан җавап көтү. Мәсәлән: “Әсма! [...] Күрешә алмасак, хуш! Муса.” (М.Җәлилнең Ә.Әбүзаровага язган хаты. 1940 ел) [Җәлил М. 1976, Б.535]. Мисалдан күренгәнчә, хат адресатка эндәшүдән башлана. Азактан имза куелып тәмамланыла.

Шәхси хатлар, гадәттә, ирекле формада язылалар. Аларда шәхси, шулай ук җәмгыяви сораулар да сөйләнергә мөмкин. Ләкин алар башка затлар өчен билгесез булалар һәм басылып чыгуга юнәлтелмиләр. Эндәшүдән соң адресатка сәлам җиткерелә. Бу төрлечә була ала. Мәсәлән, Ф.Кәримдә генә дә сәлам юллау төрле формаларда әйтелгән. Аны җиткерү адресат шәхесе белән бәйле рәвештә сайлап алына: “Кави, Сәрвәр апа! Сезгә якын туганыгыз итеп күргән фронтовик шагыйрьдән ялкынлы сәлам”. (Ф.Кәримнең К.Нәҗми һәм С.Әдһәмовага язган хаты. 1942 ел) [Кәрим Ф. 1981, Б.227]. Яки “Сөекле Кадриям, күз нурларым – кызларым! Сезгәерактан сагынычлы сәлам.” (Ф. Кәримнең К. Ишуковага язган хаты. 1943 ел) [Шунда ук, Б.281]. “Хәсән! Дусларча күп сәлам сиңа.” (Ф.Кәримнең Х.Хәйригә язган хаты. 1943 ел) [Шунда ук, Б.289].

Шәхси хатлар берничә төргә бүленәләр. Алар арасында иң киң таралганы булып күренекле шәхесләр арасында язылган хатлар тора. Мәсәлән, тарихта Х.Фәезхановның Ш.Мәрҗанигә, К.Насыйриның Н.Катановка, Г.Тукайның Ф.Әмирханга язган хатлары билгеле. Теге яки бу язучының үзенә хас язу алымнары хатлар өслүбендә дә өлешчә саклана. Г.Тукайдан бер мисал: “Фатих әфәнде. Сәлам, конечно. Хатыгызны алдым. “Әльислах”та “Кызык гыйшык” шигырен яраттыңызмы? Керпе үзенең кабыгына кереп яшеренгән төсле, мин дә сөю хакында бернәрсә язсам, ялган имзалар астына сыгынам. Язам шунда. Үзем хәзер бернәрсәне дә, беркемне дә сөймим. [...] Торам-торам да: “Ярабби! Ятимлекләр, фәкыйрьлекләр, ачлыклар, авылдан-авылга сатылып йөрүләр, рәхимсез татар байларында хезмәт итүләр, татар мәдрәсәсендә черүләр арасында да саклап килдегем истигъдад очкыны... бер дә кабынмаслык булып сүнәрмени инде?” дим. [...] Монда “Әльислах” ходка китсә, көлке журналы да чыкса, үземнең кальбән сөйгән газета һәм идеямә хезмәт итәр идем...” (Г.Тукайның Ф. Әмирханга язган хатыннан өзек. 1908 ел) [Хаков В.Х. 1999, Б.282]. 1908 елда Ф.Әмирханга җибәрелгән бу хатта Тукайга хас тыйнаклык, гадилек, кыскалык һәм нечкә юмор да ярылып ята. Сурәтләү чараларының урынлы кулланылуы, предметларның һәм күренешләрнең бер-бер артлы үстерелеп бирелүе, тиңдәш кисәкләрне үз стиленә яраклаштырып бару Тукай каләменә якынлыкны күрсәтә.

Г.Ибраһимовның “Аң” журналы нәшире Әхмәтгәрәй Хәсәнигә язган хатыннан бер өзек: “Гәрәй иптәш. Җибәрелгән китапларны алдым. Ләкин “Аң” һаман килми. Син бу хатны алгач та, миңа быелгы “Аң”нарны беренче номереннан ук башлап җибәрергә куша күр әле. Әдәбият дәресләрендә кирәкләре булгалый. Болар миңа бик матлуб. Бу хатны берничә көн элек башлап та бетерә алмый идем. Хатыңны алгач, яңадан тотындым. Башлыйк матбугат юбилееннан һәм “Аң”ның дәвамыннан. Казанда вакытта үзең белән сөйләшкәндә дә “Аң”ның тукталу ихтималыннан бик тәәссеф итүемне әйткән идем. Дәвами хәбәре хакыйкатән дә шатландырды. “Аң” тукталса, әдәбият белән яшь мәдәни фикер хакыйкатьтә бер органсыз калачак, яшь истигъдадлар өчен дә зур мәхрүмият булачак иде. Дәвам иттерергә карарында фәүкыйльгадә исабәт иткәнсең. Бу – бер минем түгел, күпләрнең фикередер...” [Күрсәтелгән хезмәт].

Тормыш-көнкүреш, сәүдә эшләре белән бәйләнешле хатлар икенче төркемне тәшкил итә. Алар да  киң таралган. Монда сәүдәгәрләр арасындагы язышулар, приказчикның хуҗасына, шәкертнең остазына, остазының шәкертенә язган хатлары һ.б. лар керә. Мәсәлән, приказчикның хуҗасына язган хаты:

“25 май, 1908 ел. Һиммәтле хуҗам әфәндем хәзрәтләре. Алып чыкдыкым малларны, базарлар килешдектән гүзәл бәһа белән сатып, үзебезгә кирәк булган малларны һәм алып, “Кавказ Меркурий” пароходы конторына бирдем. Вә бу хат белән 554 номерлы квитанцияне җибәрдем. Мәскәүдән Варшавага юл турырак булганлыктан, бәгъзе сәүдәгәрләр Варшавага баралар. Магазиннарыбызда Варшава товары булганлыктан, мин дә бергә Варшавага бармакчы идем. Җәнабыгыз мәгъкуль күрсә, күрмәсә дә, кичекмичә хат я телеграм белән хәбәр итүегезне үтенәм. Хадимегез: Салих Сабитов” [Бәширов К.Ф. 1909, Б.11].

Туганлык-кардәшлек хатлары бар. Монысы өченче төркемне тәшкил итә. Бирегә туганнар арасында язылган хатлар керәләр. Мәсәлән, ата-ананың балаларына, баланың туганнарына, туганлык мөнәсәбәтендәге төрле буын кешеләренең үзара бер-беренә җибәргән хатлары шундыйлардан. Г.Тукайның апасы Газизәгә, Ф.Әмирханның туганнарына язган хатларын һәм башкаларны алырга мөмкин.

Бер шәкертнең мәдрәсәдән әбисенә язган хатыннан өзек:

“Сөекле әбием. Моннан дүрт кенә көн элек хат язган булсам да, менә тагын язам. Язасы килә, әбием. Хәлфә дә читтән килгән шәкертләргә өйләренә ешрак хатлар язып торырга куша, һәм син дә минем хатларны алгач, шатланырыңны яхшы беләм... Әбием, җаным, бездә сыйныфта бүген бер күңелсез бер эш булды. Алдагы партада утыра торган кечерәк Заһидның әнкәсе үлгән икән. Шәкертләр Заһидны бик кызганалар. Мин дә аны бик кызганам. Иртәгә хәлфәдән мине Заһид янына утыртсын дип сорармын. Чөнки, әбием, без

икебез дә анасыз, атасызлар. Без бер-беремезне бик сөешермез. Тиздән тагын язармын. Кулыңнан үбеп, балаң Рәхимҗан. 2 октябрь, 1913 сәнә” [Күрсәтелгән хезмәт.- Б.283].

Дуслык хатлары – дүртенче төр. Бу төркемгә үзара кардәш булмаган, ләкин бер-берсе белән бик якын, самими мөнәсәбәттә торган кешеләрнең хатлары керәләр. Г.Тукайның “Ана мәктүпләре”ннән Гайшә һәм Фатыйма арасында язышкан хатлардан бер үрнәк китереп үтик.

Гайшәнең Фатыймага хаты:

“Сөекле дустым. Минем гомеремдә әле әллә нинди бер көтелмәгән эш чыгып китте. Минем үзем белән бертуган абам бар иде. Ул кисәктән генә вәйран булып үлеп китте дә, миңа тәрбиягә үзенең түп-түгәрәк ятим 5 яшьлек кызы Газизәне калдырды. Газизәнең миннән башка бер дә якын кешесе юк. Шуның өчен мин аның һәммә тормыш мәшәкатьләрен үз муеныма алырга бурычлымын. Әмма ни эшлим икән? Балалар тәрбия итәргә миндә бер дә әйтерлек көч юк. Мин аны нинди дә булса бер мәктәпкә бирергә уйлаган идем, ләкин минем хәлем бик киң түгел. Әгәр барлы-юклы хәлем берлә азапланып, барча малымны аны укытырга сарыф итим дисәм, соңыннан “ни эшләрмен?” дип куркам. Шуның өчен син дустыма киңәш итәм. Син минем хәлемне бик яхшы беләсең һәм тәрбия эшендә дә осталыгың бар. Хат яз. Миңа киңәш бир. Ходай өчен, зинһар дип әйтәм, хатыңны озынрак яз” [Күрсәтелгән хезмәт.- Б.284].

Мәхәббәт хатлары бишенче төрне тәшкил итәләр. Алар эчке кичерешләргә, эмоциональ хис-тойгыларга бай булулары ягыннан башка хатлардан аерылып торалар. “Мәхәббәт хатлары” дигән китаптан бер егетнең сөйгән кызына язган хатыннан алынган өзекне мисалга китерик:

“Мәхәббәтнең ялган булуына ышана алмыйм. Ялган булды исә мәхәббәт дип әйтеп булмыйдыр. Бу эш хатын-кызны уенчык рәвешле итеп караган тәрбиясез кешеләрдә генә булса булыр... Ялган мәхәббәт белән йөргән, адашкан кешеләрне минем вөҗданым күтәрә алмый. Вөҗданым мондый түбәнлектән ерак икәнен сезгә белдерәсе килә... Әле мин әхлак китабы язмыйммын. Сезгә әхлак үзгәртүне дә дәгъва кыйлмыймын. Бу җөмләләр сезнең сүзеңез мөнәсәбәте белән язылды... Мәхәббәт бер генә тарафтан булса ике кешенең бергә кушылуы, күңел берләшүе мөмкин түгелдер... Моннан соң сезне борчымаска чын күңелем белән иҗтиһад кылып карармын. Сезгә төшкән мәхәббәтемне эчемдә саклап үләрмен. Хушыгыз” [Шунда ук].

Шулай итеп, шәхси хатларны берничә төргә бүлеп карарга мөмкин. Аларны ачыклау өчен, хатның структурасына, сөйләм барышына һәм аралашуның эчтәлегенә игътибар итәргә кирәк. Гомумән, шәхси хатлар язу татар җәмгатьчелегендә бик киң таралган күренеш булган һәм мәгълүмат алышуда, аралушуда мөһим роль башкарган.

**Шәхси хатларга хас үзенчәлекләр**

Алдагы бүлектә без шәхси хатларның төрләргә бүленешен карап уздык. Алда карап кителгән хатлардан күренгәнчә, аларда билгеле бер таләпләрдән чыгып эш ителә һәм шул өслүбкә хас үзенчәлекләр искә алына. Бу бүлектә инде без шәхси хатларга хас стилистик, лингвистик билгеләрне ачыклыйбыз, аларның композицион төзелешен тикшерәбез. Шулай ук бу төр хатларның өслүбен карыйбыз.

Композицион-стилистик яктан караганда, хатларның күбесендә кереш, ягъни сәлам тапшыру өлеше була. Анда автор үзенең саулыгын белдерә, шуны ук мөрәҗәгать иткән кешесенә дә тели.

Шәхси хатларда бер үк төрле әйләнмәләр, сөйләм формалары кулланыла. Алар хатның эчтәлегенә карап үзгәрә дә алалар. Шәхси хатларның баштагы сәлам өлешендә төрле алымнар кулланыла. Мәсәлән, ата-ананың баласына язган хаты болай башланып китә: “Сезки йөрәгемез парәсе, ике күземез карасы, сөекле газиз фәрзандемезә хәер-догаларымызы ирсал әйләдемез”. “Кадерле дустым, мелла Кәлимуллага, барлык өй эчегез, таныш-белешләрегез белән бергә, сансыз-хисапсыз догаларыбыз күндерелә. Ислам йоласы буенча сәламнән соң, без фәкыйрьләрне барлык таяныч-якыннарыбыз белән элеккечә сау-сәламәт дип белерсез” (Ш.Мәрҗанинең Кәлимуллага язган хаты) [Күрсәтелгән хезмәт.- Б.285].

Г.Тукай баштарак туганнарына язган хатларында традицион формалар белән эш итә. 1903 елда җизнәсенә һәм Сәҗидә апасына язган хатын ул болай башлап китә: “Фөтүвәтле вә сәгадәтле җизнәмез илән миһербакә вә мөшфика Сәҗидә апайга биниһая догаи-сәламләремне васил вә мөтавасил әйләдем”. Шагыйрь сәлам өлешен бетерү белән, аңлаешлы итеп, кыска җөмләләр белән гади телдә язуга күчә: “Сез туганымның җибәргән әманәтен вә хатларыңызи ушбу үткән кышта алдым. Үзем йоклаган вакытта баш очыма куеп киткәннәр. Торып карасам, бер савыт манпаси һәм какъ тора. Соңра какыңыздан һәр апаларыма өлеш чыгардым. Бик рәхмәт укыдылар” [Шунда ук].

Хатларда сәлам өлеше башта да, уртада да, ахырда да бирелә ала. Мәсәлән, Ш.Мөхәммәдевнең З.Гобәйдуллинга җибәрелгән хатында иң элек хуҗага, хатның уртасында таныш-белешләргә, ахырында мөрәҗәгать ителгән кешенең җәмәгатенә сәлам языла. Мәсәлән, “чукдин-чук сәлам”. Биредә бу төзелмә юмор максатын үти. Кайбер хатларда сәлам булмаска да мөмкин. Мөрәҗәгать ителә торган кешенең исеме куелу белән, хатның төп эчтәлеге языла, хәбәрләр бәян ителә башлый.

Икенче өлештә хатның төп эчтәлеге бирелә, автор үзенең хәлләре белән таныштыра. Хатның озынлыгы яки кыскалыгы аның нинди шартларда язылган булуы белән бәйләнгән. Мәсәлән, мәктәп укучысының әти-әнисенә хаты балаларга хас гадилек, ихтирамлылык, сагыну хисләре белән тулы. Ул үзенең иптәшләре белән таныштырганда вакыйгаларны бөтен нечкәлекләре белән язарга ярата. Бер өзек: “Сөекле әткәм һәм сөекле әнкәм. Икегезнең дә кулларыннан үбә-үбә сәламнәремне күндерәм. Казанга килүемә менә ике җомга булса да, сезгә бер хат та яза алмадым. Бу эшем өчен, сөеклеләрем, мине ачулана күрмәгез. Хат язудан элек, мин мәктәптәге иптәшләрем белән яхшырак танышасым килгән иде. Теләгәнем булды. Иптәшләрем тугрысында сезгә дә язмакчы булам... Сул ягымда утыра торган Габдулла һаман уйланып кына утыра. Габдрахман миңа: “Син беләмсең, Закир, бит безнең Габдулла бик укыга ярата”, - диде” [Күрсәтелгән хезмәт.- Б.286].

Туры сөйләмнәр, нәзакәтле мөрәҗәгатьләр, кыска бирелгән гади сыйфатлаулар аша балаларга хас психология, мәктәптә уку, фәнне өйрәнү горурлыгы да чагылып китә. Хатларның күбесе өчен гади, җанлы сөйләм хас. Аларның эчтәлегенә бәйләнешле аерым калыплар юк. Монда күп нәрсә авторның үз ихтыяры белән бәйле. Таныш-белешләргә җибәрелгән хатларда баштагы сәлам язу булмаска да мөмкин. Мондый хатларда исем аталу белән турыдан-туры хәбәрләрне язуга күчелә, эчтәлек бирелә. Зур күләмле, озын хатлар публицистик стиль үзенчәлекләре белән үрелеп баралар. Мисал өчен үгет-нәсыйхәт рәвешендә язылган, юмор белән сугарылган театр уйнаучыларга язылган хатны алырга мөмкин.

Шәхси хатлар өслүбендәге ирекле‌лек, кыска һәм гади язарга тырышу ачык күренә. Газета-журнал исемнәре нәкъ шулай бирелгәннәр: “Кояш” тәртипсез килә”. (Г.Тукай) “Әльислах” хәзер яңадан терелеп тора”. (Ф.Ә.) Әсәр исемнәре дә метонимия рәвешендә киләләр. Мәсәлән: “Толстой сүзләренең бер-икесен бозар кебек”. (Г.Т.) “Япон сугышы” басылып чыкты”. (Ш.М.) “Бу көннәрдә “Алмашыну көннәрендә”не язып бетерәм”. (Ф.Ә.)

Сәнгатьчә сурәтләүләр, сыйфатламалар да шәхси хатлар өслүбендә шактый урын тота: “Аның кәкре-бөкре фикерләрен үзенә хаклы күрсәтеп”. (Х.Зәбири хатыннан) “Миллионщик, бай дип юан корсаклы, сыердан надан, дуңгыздан яман, эттән усал, Мәскәүне ашаучы башка татарлар да шул иблискә сәҗдә кылып йөриләр”. (Ш.М.) Хатның төрле абзацларында аерым мөрәҗәгать сүзләре, эндәшүләр урын ала. Мисаллар: “Дустым. Янә сездән бер үтенеч бар: ошбу соңгы елларда хөррият фикере кузгалгач, төрле партияләр мәйданга килде”. (Ш.М.) “Әй газиз шәкертләрем. Сезләрдән бик разыймын, күрсәткән эшләрегез тарих сәхифәләренә алтын каралар илә язылсын”. “Сез, җаннарым. Шул театрыгыз илә бөтен шәригатьне зир вә зәбәр кылдыңыз”. (“Театрчыларга мәктүп”) “Газиз углым. Хәзер сезләргә нәсыйхәт сүзләре сөйләү лазем түгел”. (“Остазыннан шәкерткә хат”) [Шунда ук].

Нәзакәтле итеп, олы ихтирам хисе белән эндәшү шәхси хатлар өслүбендәге эмоциональ-экспрессив яңгырашны тагы да күтәреп җибәрә. Бу бигрәк тә балаларның

олыларга язган хатлары өчен характерлы. Мәсәлән, укучының әбисенә адресланган хатында “Әбием җаным, бездә сыйныфта бүген бик күңелсез бер эш булды”. “Әбием, әнкәсез кечерәк Заһидка бик күңелсез булыр” кебек типтагы мөрәҗәгать итүләр шуны күрсәтәләр. Сөйләмнең аһәңе инверсияле эндәшүләрдә дә ачык чагыла: “Кечерәк Заһид бик кызганыч бит, әбием”. “Әни бик кадерле бит, әбием бәгърем”. “Язасы килә, әбием” һ.б. [Шунда ук]. Җөмләләр тулысы белән мөрәҗәгать итү, үгет-нәсыйхәт бирү рәвешендә бирелергә мөмкин. Бу очракта алар матур әдәбият әсәрендәге риторик өндәүгә якынаялар: “Газиз балам. Дөньяда файдасы булмыйча, фәкать бушка гомер уздыра торган гыйлемнәр тәхсил итәргә тырышма. Әхлак, әдәбият, тарих, хисап, җәгърәфия кеби файдалы гыйлемнәр белән танышырга тырыш. Мондый заманга – муафыйк нинди гыйлем вә фәннәр булса, лазем кадәр алырга иҗтиһат кыл. Үзләренең нәрсә сөйләгәнен белмичә, фәкать кычкырышудан гыйбарәт булган шәкертләргә карама”. (“Ата-ананың баласына хаты”) [Шунда ук, Б.289].

Шәхси хатларда телнең гадилеге җөмлә төзелешендә дә күренә. Мәсәлән, тулы җәенке җөмләдән соң, тулы булмаган җөмләләр тезелеп баруы мөмкин. Гадәттә, аларда ия кабатланмый, аны алмаштыра торган сүзләр дә кулланылмый. Г.Тукай хатларыннан бер мисал: “Ул әүвәл тазарырга, сәламәтләнергә кирәклеген сөйләде. Ютәлдән бер-ике төрле дару бирде. Кымыз эчәргә кушты” [Шунда ук]. Кайбер хатларда традицион формалар, язма китап теле үзенчәлекләре дә билгеле күләмдә урын ала.

Бу хатлар өслүбендә тел үсешендәге аерым чорларга хас гомуми тенденцияләр дә ачык чагылыш таба. Анда алынма сүзләргә һәм интернациональ лексикага шактый урын бирелә. Кайбер мисаллар: “... микроб булган тәкъдирдә дә аңар агулы дару җибәрү мөмкин түгеллеген сөйләде... Теге аспирин йоттыра торган авыру (бизгәк) күптән бетте... Вагонда буфет та бар иде”. (Г.Тукай Кәбир Бәкиргә язган хатыннан өзек) “Һәммәсе бер номерга кереп бетсә иде... цензор бозар кебек сизәм”. (Г.Тукай Зәйнәп Хәсәнигә язган хатыннан өзек) “Юлда студентлар вә курсистлар туры килә”. “Москвадагы татар вә хәтта рус аристократларыннан, хәтта бюрократларыннан әллә никадәр гаиләләр белән таныштым... Шундый вакытлар була ки, шул аристократка вә аристократларның кыланышларыннан косасылар килә”. (Ф.Әмирханның Ризван Ибраһимовка язган хатларыннан өзек).

Алынма сүзләр юмористик планда да бирелә ала. Мәсәлән: “Бер көн укыган нәрсәсен икенче көн сүз арасына кыстырып-кыстырып, ят кешеләр күбрәк җирдә рассказать итеп чыга”. “Әгәр азанны да татарчага переводить итсә, аннан соң тәмам зур мөхәррирлекнең камәленә ирешкән булыр иде”. (Ф.Әмирханның И.Аитовка хаты) [Шунда ук]. Биредә юмористик эчтәлек әдәби норма итеп кабул ителмәгән инфинитив формадагы рус фигыльләре белән тагы да көчәя төшә. Гипербола рәвешендә дә юмористик сөйләм барлыкка килә ала: “Барысына да бер вагон сәлам”. (Ш.М.) Кайбер алынма сүзләр халык сөйләмендәгечә үзгәртелеп биреләләр: “Програмсыз улдыктан”. “Ике еллык җүбәләе була бит”. (Г.Тукай) “Баласы җәл калган” (Ш.М.) Хатларда стихия рәвешендә халык сөйләменә үткән, әмма әдәби тел өчен норма булып саналмаган сүзләр дә очрый. Мәсәлән: “Эчем, тышым Ишми вә игъванына злоба белән тулды” (Г.Т.) [Тукай Г. 1976, Б.334]. “Впрочем, акча юклыктан бик күп вакыты җиткән дәваларны кылмый торырга туры килә”. “Бөтен удовольствием дә хәзер шул көн саен редакциягә чыгудан гына гыйбарәт” (Ф.Ә.) [Хаков В.Х. 1999, Б.290].

Димәк, шәхси хатлар мөһим, тарихи документ кына түгел, ә өйрәнү өчен бай һәм кызыклы тел материалы булып тора. Аларны өйрәнеп, без анализларга, чагыштырырга, төрле чорларда, стильләрдә язылу нормаларын ачыклый алабыз.

Шәхси хатлар әдәби жанр белән дә тыгыз үрелеп килә. Матур әдәбият әсәрләрендә еш кына шул үзенчәлекне күзәтергә мөмкин. Мондый очракларда хатларның теле, язылу алымнары шул әсәрнең теленә һәм авторга хас үзенчәлекләргә яраклаштырылып бирелә.

Шәхси хатлар эпистоляр жанрның үсешенә этәргеч биргәннәр. Бу формада хат язышу фикер алышу чарасы гына булып калмады, ә җәмгыятьнең сәнгать өлкәсендәге аерылгысыз элементы булып калды.

Шәхси хатларда татар проза теленең формалашуы да ачык күренә. Сөйләм гади һәм катлаулы төзелмәләрдән оеша, төрле әйләнмәләр кулланыла, фикер ачык һәм билгеле бер логик эзлеклелектә бирелә. Болар барысы да телнең эчке мөмкинлекләреннән дөрес файдалануны таләп итә. Нәтиҗәдә, бу башка өслүбләрне дә яңа үзенчәлекләр белән баетырга, әдәби телнең функциясен киңәйтергә мөмкинлек бирә. Җөмләләрне дөрес төзү, урынлы куллану төрле вариантлар белән эш итә белүгә дә бәйләнгән. Бер үк контекстта фигыльләрнең төрле төрләреннән, барлык-юклык һәм заман формаларыннан файдаланыла. Бу да сөйләмнең стилистик нәтиҗәлелеген булдыруга, көчәйтүгә хезмәт итә. Болар белән беррәттән, фикерне укучының һәм тыңлаучының аңына җиткерү өчен башка тел-сурәтләү алымнары да катнаша. Бу юнәлештә сөйләмдә риторик сораулар, өндәүләрнең төрле кабатлаулар белән бергә тыгыз үрелеп баруын, кучерелмә мәгънәдәге сүзләрнең киң кулланылуын күрергә мөмкин.

Димәк, шәхси хатлар - бик тә үзенчәлекле төр. Алар үзләре дә берничә төркемгә бүленәләр. Бу ике якын субъектның хат язышуы итеп карала. Әлеге хатлар тел-стиль ягыннан да бик бай. Без бу хатларга хас төп лингвистик, стилистик билгеләрне, тел-сурәтләү чараларын ачыкладык. Әлеге үзенчәлекләр күренекле әдипләребезнең хатларында тулысынча чагылыш таптылар.

Без әлеге фәнни хезмәтебездә шәхси хатларның төрләрен ачыкладык һәм аларга хас төп үзенчәлекләрне билгеләдек. Гомумән, шундый нәтиҗәгә килергә мөмкин: әлеге төр хатлар эпистоляр стильдә иң мөһим бер тармак булып тора һәм үзенең төзелеше, эчтәлеге, формасы, кулланылыш даирәсе белән аерылып тора.

Галимнәрнең шәхси хатларга карата фикерләре төрле. Аларның төрләрен билгеләүдә дә аерымлыклар күзәтелә. Шулай да, без шәхси хатларның биш төрен аерып күрсәттек.

Шәхси хатларны язуда үзенә генә хас калыплар да бар. Бу структур яктан сакланырга тиеш. Мәсәлән, шәхси хатлар композицион яктан өч өлештән тора: кереш, төп өлеш, йомгаклау. Шулай да без, алдагы хат үрнәкләреннән карап киткәнчә, аларда бу форма иректе кулланылган вариантлар да очрый. Шәхси хатларда адресатка эндәшүдән башлана, ләкин барлык хатларда да әлеге үзенчәлек сакланмаска мөмкин. Хат азагына дата һәм адресантның имзасы куела.

Хат, адресат шәхесенә карап, төрле эчтәлектә, башка төрле мөнәсәбәттә була. Шуны исәпкә алып, төрле тел-сурәтләү чаралары кулланылып языла. Мәсәлән, без карап үткән Ф.Кәрим, Г.Тукай хатларында әлеге үзенчәлек аерып күрсәтелде.

Шәхси хатларда тормышны, яшәешне сурәтләү зур урын ала. Алар аша без адресантның тел үзенчәлекләрен, дөньяга карашын, аңа хас сыйфатларны ачыклый алабыз. Хат язышу диалог формасына корылган яки аны монологка корылган диалог дип тә әйтеп була. Анда ике аралашучы була. Әлеге форманы без шулай ук Ф.Кәримнең хатларыннан карап үттек.

Шулай ук, шәхси хатлар тиз вакыт эчендә язылалар, андагы кимчелекләрне төзәтү, кытыршылыкларны шомарту яки күчереп тору гадәте бөтенләй юк. Шуңа күрә анда гади сөйләү теленең традицион язма формалары белән аралашып килүен дә, фикерләрнең кабатлануын да һәм индивидуаль язу үзенчәлекләрен дә күрергә мөмкин. Алар төрле функция башкаралар: танып белү, коммуникатив, фатик (элемтә урнаштыру) һ.б.

Бүгенге көндә шәхси хат язышу күренеше кими бара. Телдән сөйләм функцияләренең артуы язма рәвештә аралашуны киметә бара (телефон аша аралашу). Дуслар һәм туганнар язма формада бик сирәк аралашалар. Алар урынына SMS-хәбәр, электрон почта аша җибәрелә торган текстлар, чат, форум, сайт, мессенджер битләрендә аралашу киң таралды. Открыткалар (ачык хатлар) хәзерге көндә билгеле бер шаблонга салынганнар. Аларда бары тик дата һәм кемгә юнәлдерелгәнлекне генә күрсәтәсе кала.

Шулай итеп, тарихи шартлар үзгәрү сәбәпле, шәхси хатлар бүгенге көндә икенче үсеш-үзгәреш этабына аяк бастылар. Шуңа күрә аларга кагылышлы проблемалар да аз түгел. Мәсәлән, традицион хат язу формасы бүгенге көндә кимегәннән кими бара, чөнки кешеләр күбрәк үзара телефоннан аралашалар. Шулай да хәзерге вакытта шәхси хатларны тикшерү

буенча актив эш алып барыла һәм аларның башка өйрәнелмәгән үзенчәлекләре ныклап тикшерелә. Бу фәнни хезмәтебезнең төп максаты шәхси хатларга хас булган үзенчәлекләрне күрсәтү иде, һәм без куйган максатыбызга тулысынча ирештек.

*Кулланылган әдәбият:*

1. Авхадиева А.И. История изучения эпистолярного стиля в татарском языкознании / А.И. Авхадива // Востоковедение. Сборник статей и докладов / Отв. ред. Г.Г. Зайнуллин.- Казань, 2003.- 149 с.

2. Ахманова О.С. Словарь лингвистических терминов / О.С. Ахманова.- Москва: Сов. Энциклопедия, 1969.- 608 с.

3. Әмирхан Фатих Әсәрләр, 4 томда. 4 т. Әдәби сәнгать тәнкыйте, биографик материаллар, хатлар / Фатих Әмирхан.- Казан: Тат. кит. нәшр., 1986.- 390 б.

4. Әүһәдиева А.И. Татар телендә эпистоляр стильнең формалашуы / А.И. Әүһәдиева // Татар теле, әдәбияты, тарихы-үткәне һәм бүгенгесе / Баш ред. Т.Н. Галиуллин.- Казан: Казан унив. нәшр., 2000.- 446 б.

5. Бәширов К.Ф. Хат язмак ысулы / К.Ф. Бәширов.- Казан: Типо-литография Императорского университета, 1909.- 17 б.

6. Виноградова Е.М. Эпистолярные речевые жанры: Прагматика и семантика текста / Е.М. Виноградова.- Москва: Московский государственный заочный педагогический институт, 1991.- 20 с.

7. Гыйззәтов Таҗи Сайланма әсәрләр, драмалар / Таҗи Гыйззәтов.- Казан: Тат. кит. нәшр., 2002.- 384 б.

8. Җәлил Муса Әсәрләр, 3 томда. 3 т. Шигырьләр, поэмалар, тәрҗемәләр, биографик материаллар, хатлар / Муса Җәлил.- Казан: Тат. кит. нәшр., 1976.- 648 б.

9. Зиннәтуллина К.З. Татар теле: Рус телендә урта гомуми белем бирүче мәкт. 9 нчы сыйныфы өчен дәреслек (татар балалары өчен) / К.З. Зиннәтуллина, Ф.Ф. Фатыйхова, Р.Х. Мирзаһитов.- Яңартылган 3нче басма.- Казан: Мәгариф, 2005.- 159 б.

10. Зәкиев М.З. Туган тел үсеше / М. Зәкиев.- Казан: Тат. кит. нәшр., 1967.- 83 б.

11. Ибраһимов С.М. Синтаксик стилистика: Студентлар өчен кулланма / С. Ибраһимов.- Казан: Казан унив. нәшр., 1989.- 150 б.

12. Кәрим Фатих Әсәрләр, 3 томда. 3 т. Повестьлар һәм хикәяләр, мәкаләләр, очерклар, хатлар / Фатих Кәрим.- Казан: Тат. кит. нәшр., 1981.- 327 б.

13. Курбатов Х.Р. Сүз сәнгате: Татар теленең лингвистик стилистикасы һәм поэтикасы / Х.Р. Курбатов .- Казан: Мәгариф, 2002.- 199 б.

14. Ризаэтдин Фәхретдин: Фәнни биографик җыентык / Ризаэтдин Фәхретдинов.- Казан: “Рухият” нәшр., 1999.- 224 б.

15. Сафиуллина Ф.С. Татар теле: Рус урта гомуми белем мәктәбе 11нче сыйныфында укучы татар балалары өчен дәреслек / Ф.С. Сафиуллина, С.М. Ибраһимов.- Тулыландырылган 2нче басма.- Казан: Мәгариф, 2000.- 175 б.

16. Седова О.Н. Эпистолярный стиль в системе функциональных стилей русского языка / О.Н. Седова // Филологические науки, 1985.- №5.- С.57-60.

17. Такташ Һади Әсәрләр, 3 томда. 3 т. / Һади Такташ.- Казан: Тат. кит. нәшр., 1983.- 478 б.

18. Татар стилистикасының теоретик нигезләре: Татар филологиясе һәм тарихы факультеты студентлары өчен программа / Төз. И.Б. Бәширова.- Казан: Казан дәүләт унив. нәшр., 2005.- 29 б.

19. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге / Баш ред. Ф.Ә. Ганиев; сүз башы авт. Ф.Ә. Ганиев; ТР ФА Г.Ибраһимов ис. ТӘһСИ гыйльми советы карары белән басыла.- Казан: Матбугат йорты нәшр., 2005.- 848 б.

20. Тукай Габдулла Сайланма әсәрләр, 2 томда. 2 т. Мәкаләләр, истәлекләр, хатлар / Габдулла Тукай.- Казан: Тат. кит. нәрш., 1976.- 447 б.

21. Хаков В.Х. Татар әдәби теле (стилистика) / В. Хаков.- Казан: Тат. Кит. нәшр., 1999.- 304 б.
22. Хаков В.Х. Татар милли әдәби теленең барлыкка килүе һәм үсеше / В. Хаков.- Казан унив. нәшр., 1972.- 222 б.
23. Хаков В.Х. Тел һәм стиль мәсьәләләре / В. Хаков.- Казан: Казан унив. нәшр., 1961.- 160 б.

## ТАТАР ТЕЛЕНДӘ КОШ АТАМАЛАРЫ КЕРГӘН ФРАЗЕОЛОГИЗМНАР

*Илсаф Габизов, 10нчы сыйныф укучысы,*
*Фәнни җитәкчесе: Сабирова Резеда Әгъзамтин кызы,*
*Саба районы Шәмәрдән лицее*

Фразеологик әйтелмәләр телдә гаять әһәмиятле роль уйный.Адар, гади сүз һәм сүзтезмәдән аермалы буларак, фикерне, төшенчәне сурәтле, бизәкле, тәэсирле итеп белдерәләр. Кеше үене сөйләмендә фразеологик әйтелмәләрне никадәр мул һәм уңышлы файдаланса, аның фикере кешеләргә шул дәрәҗәдә җиңелрәк, тизрәк һәм тәэсирлерәк барып җитә.

Фразеологизмнарда халыкның тормыш тәҗрибәсе, фикер йөртүе, милли үзенчәлекләре чагылыш таба. Аларның барлыкка килүе дә кешенең абстракт, метафорик уйлау сәләте үсеше белән бәйле, ягъни фразеологизмнар әйберләрне, күренешләрне бер - берсенә охшатып, чагыштырып барлыкка килә. Аерым очракларда төрле телләрдәге фразеологик әйтелмәләр уртак юллар белән барлыкка килә. Мәсәлән, плясать под чужую дудку - кеше кубызына бию. Бу форманы бер телдән икенче телгә тәрҗемә ителгән дию дөрес түгел, чөнки төрле халыкның фикерләү законнары уртак. Әлеге формалар шул уртаклык җирлегендә барлыкка килә. Фразеологизм барлыкка килүнең иң бай чыганагы булып халыкның җанлы сөйләме санала. Аларның шактый күп өлеше халык авыз иҗатыннан алынган: ай күрде - кояш алды. Кайберләренең килеп чыгышы билгеле бер җиргә бәйле була: башына тай типмәгән. Шулай ук фразеологизмнар билгеле бер һөнәр иярәреннән килеп чыгарга мөмкин: ат ачуын тәртәдән алу. Фразеология фонды әдәби, тарихи чыганаклар нигезендә дә байый. Кайбер фразеологизмнар чит телдән калькалаштыру юлы белән дә белдерелә. Бер өлеше дини чыганакларга барып тоташа: сират күпере аша чыгу. Грек мифологиясеннән алынганнары да шактый: акчаның исе юк, ызгыш алмасы. Шулай ук халыклашкан әсәрләрнең персонажлары фразеологик берәмлекләргә әвереләләр: Таһир - Зөһрә.

Халыкның күп гасырлар дәвамындагы күзәтүләре һәм уйланулары нәтиҗәләре, аның хыял-өметләре дә тотрыклы сүзтезмәләрдә гәүдәләнеш таба. Кеше табигать баласы дип юкка гына әйтмиләр, чөнки безнең көнкүрешебез, мөһитебез һәрчак табигатькә – төрле кыргый җәнлекләр, йорт хайваннары, үсемлекләр һәм, әлбәттә, кошлар белән бәйле. Бигрәк тә бу бәйләнеш фразеологик сүзтезмәләрдә ачык күренә. Мәсәлән, кешенең тышкы кыяфәтен, холык-фигылен тотрыклы сүзтезмәләр аша еш кына бирәбез: торна Вәли- бик озын буйлы, ике бозауга кибәк аера белмәгән- кулыннан эш килми торган, булдыксыз, уңмаган, җебегән. Әлбәттә, татар теленең фразеологик берәмлекләре лексик составы ягыннан тиешле дәрәҗәдә өйрәнелгән. Мондый тотрыклы берәмлекләр составында кош исемнәренең кулланылышы зур кызыксыну уята. Шул сәбәпле без фәнни-тикшеренү эшебезне кош исемнәре белән бәйле фразеологик әйтелмәләрне өйрәнүгә багышладык һәм “Татар телендә кош атамалары кергән фразеологик берәмлекләр” дип атадык. Бу тема бездә кызыксыну уятты һәм фразеологик берәмлекләр составында кош исемнәренең ни дәрәҗәдә кулланылуын ачыклау максатын куйдык. Максатка ирешү өчен түбәндәге бурычлар куелды:

1) фразеологиягә багышланган фәнни-методик хезмәтләргә күзәтү ясау;

2) “Татар теленең фразеологик сүзлеге”нә күзәтү ясау, алардан кош исемнәре кергән фразеологик әйтелмәләрне язып алу;

3) әлеге фразеологизмнарны төзелеше һәм семантик яктан тикшерү.

Тикшерү объекты итеп, Н.Исәнбәтнең ике томлык “Татар теленең фразеологик сүзлеге” н алдык.

Хезмәтнең практик әһәмияте: мәктәп, урта, югары уку йортларында фразеологик әйтелмәләр темасын өйрәнгәндә ярдәмлек буларак кулланма материал булып хезмәт итә алуында.

**Татар телендә кош атамалары кергән фразеологик берәмлекләр.**

**“Кош” сүзе кергән фразеологик берәмлекләр.**

Теләсә кайсы халык билгеле бер тирәлектә яши һәм шулай ук аны географик яктан шушы тирәлеккә яраклашкан үсемлек, хайваннар, кошлар дөньясы чолгап ала. Кошлар - Җир йөзендә иң киң таралган тереклек иясе. Хәзер аларның бик күп төрләре бар. Җир шарында 9600 төрле кош яши.. Мәсәлән, без яши торган Татарстанда гына да 200 ләп төре бар. Нинди генә кошларны очратмыйсың безнең туган җиребездә: карга, саескан, сыерчык, күгәрчен, сандугач, көртлек.... Шуңа күрә тукран, каз, күке, тургай,чәүкә кебек кош атамалары татар халкының сөйләмендә канатлы әйтелмәләр, тотрыклы сүзтезмәләр, мәкаль-әйтемнәр составында да кулланылалар. Мәсәлән, сөйләмдә дә, төрле әдәби әсәрләрдә дә “кош” сүзе кергән фразеологик әйтелмәләр киң кулланыла. Мәсәлән, “Асыл кош”, “Бәхет кошы”, “Күңел кошы”, “Оҗмах кошы” һәм башкалар. Н.Исәнбәтнең ике томлык “Татар теленең фразеологик сүзлеге” ндә “кош” сүзе кергән 19 фразеологик әйтелмә бирелгән.[13] Әлеге фразеологизмнар кошларның төрле сыйфатларын, яшәү рәвешләрен күзәтү нәтиҗәсендә барлыкка килгән. Мәсәлән, кошның җитезлеге, тиз һәм еракка очуы белән бәйле фразеологизмнар: “Кош очып җитмәс җир”, “Кош очымы”, “Кош очмас җирдән”. “Кош токтандай” фразеологизмы да кошның җитезлеге белән бәйле. Очкан кошны тоту мөмкин булмаган кебек, адәм баласы да һәр теләгенә ирешә алмый. Әгәр инде кечкенә генә теләгенә ирешеп, бик нык шатланса, кош токтандай була, чөнки кош бик сирәк очракта гына тоттыра. Шушы чагыштыру җирлегендә кош токтандай фразеологизмы барлыкка килгән. “Кош сөте генә юк” фразеологизмы җаның ни тели бар да бар, кошның сөте булса, анысы да булыр иде дигәнне аңлата. Борынгы грекларда да киң таралган. Аристофан, Лукман һәм башкалар да әлеге фразеологизмны мисал итеп китерәләр. Аларда: байлык белән мөмкин булмаган нәрсәне дә табып була дигән мәгънәдә. Рус халкында да киң таралган: “Всё есть у богатого, оприч птичьего молока”.

**Кош атамалары белән бәйле фразеологик берәмлекләрне семантик яктан төркемләү.**

Кешенең тышкы кыяфәтен, холык-фигылен еш кына төрле кош атамалары кергән тотрыклы сүзтезмәләр аша бирәбез. Шуңа күрә безнең тарафтан кош атамалары белән бәйле фразеологик әйтелмәләр семантик яктан тикшерелде. Кош атамалары белән бәйле фразеологик берәмлекләр төрле мәгънәләрне белдереп килергә мөмкин. Бер ишеләре предметны һәм затны белдерсә, бер ишеләре шул предмет һәм затларның билгеләрен, сыйфатларын, эш-хәлләрен белдереп киләләр. Мәсәлән, “каз оясы” – тузган өй, мамыгы-йоны тузган зур бүрекне(предметны) белдерсә, “каз мамыгы аның башында” фразеологизмын ялганчы кешегә карата кулланалар, ягъни аның эчке сыйфатын тасвирлап бирә. “Каз урынына карга” фразеологизмы исә эш-хәлне белдерә. Әйбәт нәрсә көткәндә, начары эләгү, алдану мәгънәсен аңлата.

Шушы бүленешне истә тотып, кош атамалары белән бәйле фразеологизмнарны 3 төркемгә бүлдек: предмет һәм зат белән белдерүче, билге һәм сыйфатны белдерүче, эш-хәлне белдерүче фразеологизмнар.

---

[13] Кушымта 1

Әйтергә кирәк, предмет һәм затларның билгеләрен, сыйфатларын белдерүче фразеологизмнар аеруча күп. Алар.тупланылган 192 фразеологик берәмлекнең өчтән ике өлешен тәшкил итә.

Кешенең тышкы кыяфәтен, холык-фигылен еш кына төрле кош атамалары кергән тотрыклы сүзтезмәләр аша бирәбез. Кешенең ялгызлыгын күкегә тиңләп күрсәтү фразеологизмнарда сакланып калган. Күке – баласыз ялгыз кош. Аның йомыркасын чит кош оясына салып калдыруы гомуммәгълүм. Татар халкы аның шушы билгесен күздә тотып, баласыз, тол яки буйдак кешегә карата әйтелгән фразеологизмнарда нәкъ менә күкегә тиңләүне кулланалар: *"оясыз кәккүк" , "дуадак күке төсле".* Башкаларга катышмый торган ят кешегә карата *"ак күке - ят күке"* фразеологизмы да еш кулланыла. Күкенең оясын эзләп кычкырып йөрүе дә халык күз уңыннан читтә калмаган. *"Саташкан күке", тиле кәккүк", "аңгыра күке"* фразеологизмнары аңгыраеп йөри торган, кеше сүзен кабатлап, мәгънәсез сөйләүче кешегә карата кулланыла. *"Күке җан"* фразеологизмы исә моңы-җыры белән кешене әсир итүчегә карата кулланыла. Гомумән, "күке" белән бәйле фразеологизмнар шактый һәм аларның күбесе кешедәге тискәре сыйфатларны чагылдыралар.

"Сандугач" атамасы кергән фразеологизмнар күбрәк кешенең уңай сыйфатларын чагылдыралар. Мәсәлән, эше уңышлы барган кешегә *"аның сандугачы сайрый"* , ә бик уңган, оста куллы кешегә карата *"агачтан сандугач кына ясамый",* диләр. Шулай ук кешедәге кайбер кимчелекле сыйфатны белдерү өчен дә "сандугач" атамасы белән бирелгән фразеологизмнар бар. Кеше алдына чыгып, кәгазьгә карамыйча, үз сүзен әйтә алмаучы кешене *"кәгазь сандугачы"* дисәләр, аз йоклаучы кешегә карата *" сандугач йокысы"* белән йоклый диләр. Гомумән, "сандугач" атамасы кергән 10 фразеологизмның 6 сы кешенең уңай сыйфатын чагылдырса, 4 се аз гына кимчелеген күрсәтә.

Күзәтүләрдән күренгәнчә, һәр кош атамасы нинди дә булса сыйфатны чагылдыру өчен кулланыла. Мәсәлән, күбесенчә тавык компонентлы фразеологик берәмлекләр аңгыралыкны, зиһенсезлекне, белемсезлекне, үрдәк – сер тотмаучанлыкны, күп сөйләшүчәнлекне, алдауны, саескан – эләкчелекне, ялганлауны, чебеш- хәлсезлекне, чирләшкә булуны, күркә- мактанчыклыкны , тилгән- тилелекне белдерә. Кош атамалары кергән фразеологизмнарның бер ишеләре кешене тышкы яктан сурәтләсәләр, икенчеләре исә кешенең эчке күңелен тасвирлыйлар. Кешенең тышкы төс-кыяфәтен тасвирлаучы фразеологик әйтелмәләр симезлек, ябыклык, ямьсезлек, озын буйлы һәм кара мыеклы булу кебек сыйфатларны һәм үзенчәлекләрне характерлап киләләр. Алдан ук шуны әйтергә кирәк: кешенең тышкы кыяфәтен сурәтләүче кош атамалары белән белән бәйле тотрыклы сүзтезмәләр шактый аз. Мәсәлән, "*такыр басу торнасы кебек"-озын буйлы, "карга куркыткычы"- ямьсез, "карга чукырлык та ите калмага"-ябык, "карлыгач мыек"- кара мыеклы* һ.б.

Эчке күңел сыйфатларын характерлап килүче фразеологик берәмлекләргә килгәндә, алар кешенең үткер телле, әрсез, саран, алдау, аңгыра, надан, тиктормас, курку, ялкау, булдыксыз, җиңел акыллы, мактану, сер тотмау, күп сөйләү, сүзендә тормау, җитезлек, сизгерлек кебек сыйфатларны белдерә. Мәсәлән, "*чыпчык йөрәк"- куркак, "бытбылдык сату"- күп сөйләү, "борынына тугыз күркә кунарлык"- мактанчык, "карга маен эчкән"- аңгыра, "тавык баш"- зиһенсез, "карт чыпчык"- тәҗрибәле* .

Кош атамалары кергән фразеологик әйтелмәләрне тикшерү шуны күрсәтте: кешенең уңай сыйфатын күрсәтүче фразеологик берәмлекләр кешенең кире сыйфатын белдерүче берәмлекләргә караганда бик аз. Кешене кире характерлаучы фразеологизмнар алдау, нәселсезлек, кирелек, саранлык, начарлык, сер тотмау, курку, булдыксыз, мактану, игътибарсызлык,, җиңел акыллылыкны һ.б. белдерә. Мәсәлән, *"каз урынына карга"-алдау, "тол ата каз сыман"- үзеннән нәсел калдырмаучы,"тавык кебек киригә тырнау"- киресен эшләүче,"тавык үләте"- начарлык, зәхмәт таратучы кеше, "үрдәк телен ашаган"- бакылдык, "калай әтәч"- шапырынырга яратучы, буш кеше, "карга санап йөрү" - ачык авыз булу* һ.б. Кешенең уңай сыйфатлары халык тарафыннан кагыйдә буларак кабул ителә, ә тискәре яклары игътибарны җәлеп итә, шуңа күрә негатив яктан характерлаучы әйтелмәләр

күбрәк очрый. Шулай ук кайсы кош атамасы белән фразеологизмнар күбрәк булуын ачыкладык Нәтиҗәдә тавык компоненты булган 36; каз – 26, карга – 19, чыпчык– 15; торна – 11, сандугач һәм күке – 10; әтәч – 8, ябалак - 6, үрдәк – 5; күркә, чәүкә, күгәрчен, ала карга – 4, аккош, тутый кош, чебеш – 3, карлыгач, козгын, бүдәнә, карчыга, тартар, тилгән – 2, тургай, тукран, сыерчык, бөркет– 1 фразеологизм барлыгы ачыкланды.[14]

**Кош атамалары кергән фразеологизмнарны компонентлары буенча төркемләү.**

Сан ягыннан фразеологизм составында икедән алып алты-җиде сүзгә хәтле компонент булырга мөмкин.

| ***Ике компонентлы*** | ***Өч компонентлы*** | ***Дүрт компонентлы*** |
|---|---|---|
| *Аккош сөте* | *Аккош очырып баеган* | *Ак күке-ят күке* |
| *Аккоштан ычкындыру* | *Дуадак күке төсле* | *Иске мәчеткә күккүк мәзин* |
| *Аңгыра күке* | *Акчасыздан ата каз* | *Ата казга сәлам бирү* |
| *Күке паровоз* | *Ата каз боткасы* | *Ата казыгыз күкәй саламы* |
| *Күке төкереге* | *Каз тәне чыгу* | *Каз биреп үрдәк алу* |
| *Күке җан* | *Каз урынына карга* | *Каз булсаң симез бул* |
| *Оясыз- кәккүк* | *Каз ите күтәрелү* | *Каз мамыгы аның башында* |
| *Саташкан күке* | *Казлар Рим коткарган* | *Капчык-капчык каз башы* |
| *Тиле кәккүк* | *Каз мамыгына утыру* | *Оя баскан каз кебек* |
| *. Каз мае* | *Каз муен булу* | *Оясын пычраткан каз кебек* |
| *Киек каз юлы* | *Авызыңа каз боты* | *Тол ата каз сыман* |
| *Бөрешкән тавык* | *Авызыңа каз мае* | *Акчасын тавык та чүпләп бетермәс* |
| *Йолкынган тавык* | *Аның тавыгы юргалый* | *Алмаган тавык, салмаган йомырка* |
| *Каткан тавык* | *Тавык атлап чыгарлык* | *Тавык белән сабан сөрү* |
| *Кикрикле тавык* | *Тавык бәкәленнән йөзә* | *Тавык бүтәкәсеннән энҗе эзләү* |
| *Койрыксыз тавык* | *Тавык мие эчкән* | *Тавык кебек артка тырнау* |
| *Оя тавыгы* | *Тавык чүпләп бетергесез* | *Тавыклар куначадан төшмәс борын* |
| *Сукыр тавык* | *Әтәче дә күкәй сала* | *Тавык күлендә йомырка бетмәгән* |
| *Тавык абзары* | *Кара чәүкә кебек* | *Тавык сыман кирегә тырмый* |
| *Тавык аягы* | *Аның сандугачы сайрый* | *Акчасы әтәч булып кычкыра* |
| *Тавык баш* | *Карлыгач-сандугач булышу* | *Аның әтәче дә кубыз уйный* |
| *Тавык елы* | *Сандугачны каргага алыштыру* | *Йомыркадан чыкканчы әтәч булган* |
| *Тавыу йөрәк* | *Карлыгач-сандугач булышу* | *Әтәч булып кычкыра акчасы* |
| *Тавыклар көләрлек* | *Үрдәк телен ашаган* | *Әтәч кебек кукыраеп йөрү* |
| *Тавык хәтере* | *Бер оя чебешләре* | *Алап сугып чәүкә куркытма* |
| *Тутырган тавык* | *Торна йомыркасын тоттыру* | *Чәүкә мие эчкән нәрсә* |
| *Тавык үләте* | *Торна борчагы сибү* | *Агачтан сандугач кына ясамый* |
| *Беренче әтәч* | *Торнаның ыштаны юк* | *Син сандугач, мин карлыгач* |

[14] Кушымта 2

| | | |
|---|---|---|
| *Тол әтәч* | *Карга маен эчкән* | *Сандугач койрыгы борып алу* |
| *Калай әтәч* | *Карга санап йөрү* | *Сандугач теле кирәкме сиңа* |
| *Әтәч итү* | *Каргышың карга башына* | *Самавыр башында сандугач сайрату* |
| *Әтәч гомер* | *Карчыга булып ташлану* | *Артыннан тере саескан очыра* |
| *Әтәч какрыгы* | *Күгәрчен кебек гөрләшү* | *Авызыннан тере саескан очыра* |
| *Әтәч куразы* | *Тартай арбасы кебек* | *Борынына тугыз күркә кунарлык* |
| *Әтәч азан* | *Тартай кебек арык* | *Күкәй баскан күркә шикелле* |
| *Чиркәү чәүкәсе* | *Тилгән күкәе эчкән-* | *Такыр басу торнасы кебек* |
| *Кәгазь сандугачы* | *Тилгән мие ашаган* | *Каргага аттым, бозауга тиде* |
| *Сандугач йокысы* | *Чыпчык башы кадәр* | *Карга оясында үскән күккүк* |
| *Карлыгач мыек-* | *Чыпчыкның да үз бизмәне* | *Карга чукырлык та ите калмаган* |
| *Сертотмас үрдәк* | *Чыпчык оясы кебек* | *Карга җимгә төшмәс борын* |
| *Үрдәк очыру* | *Чыпчык чүпләп бетермәс* | *Тавис каурыйлары таккан карга* |
| *Күзге чебеш* | *Ак ябалак сөте* | *Карчыгадан калган тавык шикелле* |
| *Чирле чебеш* | *Ябалак үлгән урын* | *Күгәрчен сөте генә юк* |
| *Дагалы күркә* | | *Ала каргадай алдан кычкыру* |
| *Бытбылдык сату* | | *Ала каргадай кайтып та җиткән* |
| *Кара козгын* | | *Чыпчыкка йон чыкканны да сизү* |
| *Бәлеш козгыны* | | *Чыпчык күреп коты очкан* |
| *Бүдәнә сугыштыру* | | *Чыпчык чукырлык ит калмау* |
| *Бүдәнә симертү* | | |
| *Торна Вәли* | | |
| *Йонсыз торна* | | |
| *Торна кунагы* | | |
| *Торна мамыгы* | | |
| *Торна күзе* | | |
| *Торна юлы* | | |
| *Һавадагы торна* | | |
| *Кара карга* | | |
| *Карга бураны* | | |
| *Карга авыз* | | |
| *Карга куркыткычы* | | |
| *Карга боткасы* | | |
| *Мисыр каргасы* | | |
| *Кара кош* | | |
| *Күгәрчен сөте* | | |
| *Күгәрчен ашату* | | |
| *Ала кош* | | |

| | | |
|---|---|---|
| *Сыерчык бураны* | | |
| *Тутый кош* | | |
| *Тукран тәүбәсе* | | |
| *Тургай тубыгыннан* | | |
| *Карт чыпчык* | | |
| *Кино чыпчыгы* | | |
| *Чыпчык баш* | | |
| *Чыпчык ите* | | |
| *Чыпчык йөрәк* | | |
| *Чыпчык тезеннән* | | |
| *Ябалак шулпасы* | | |
| *Ябалак баш* | | |
| *Чырайсыз ябалак* | | |

Кош атамалары кергән фразеологизмнарны ничә компоненттан торуын ачыклау шуны күрсәтте: ике компонентлы тотрыклы сүзтезмәләр өч, дүрт компонентлыларга караганда күбрәк. Шулай ук биш һәм аннан да күбрәк компоненттан торган фразеологизмнар да очрады. Мәсәлән, *"чыпчык пыр иткәнгә йөрәге шыр итә", "чыпчык кебек бер ботакта тормас", " кебек йөрим дип, үз йөрүен оныткан саескан хәлендә калу",* **"***карга көйгә "сандугач" дип йөрү"***,** **"***карга башыдай калҗа таба алмассың", "карганы сабынлап юу белән бер" һәм башкалар.*

Шулай итеп, кош атамалары кергән фразеологик әйтелмәләрне тикшерү шуны күрсәтте: кешенең уңай сыйфатын күрсәтүче фразеологик берәмлекләр кешенең кире сыйфатын белдерүче берәмлекләргә караганда бик аз. Кешене кире характерлаучы фразеологизмнар алдау, нәселсезлек, кирелек, саранлык, начарлык, сер тотмау, курку, булдыксыз, мактану, игътибарсызлык,, җиңел акыллылыкны һ.б. белдерә. Мәсәлән, *"каз урынына карга"-алдау, "тол ата каз сыман"- үзеннән нәсел калдырмаучы,"тавык кебек кирегә тырнау"- киресен эшләүче,"тавык үләте"- начарлык, зәхмәт таратучы кеше, "үрдәк телен ашаган"- бакылдык, "калай әтәч"- шапырынырга яратучы, буш кеше, "карга санап йөрү" - ачык авыз булу* һ.б. Кешенең уңай сыйфатлары халык тарафыннан кагыйдә буларак кабул ителә, ә тискәре яклары игътибарны җәлеп итә, шуңа күрә негатив яктан характерлаучы әйтелмәләр күбрәк очрый.

Шулай ук кайсы кош атамасы белән фразеологизмнар күбрәк булуы ачыкланды. Нәтиҗәдә тавык компоненты булган 36; каз – 26, карга – 19, чыпчык– 15; торна – 11, сандугач һәм күке – 10; әтәч – 8, ябалак - 6, үрдәк – 5; күркә, чәүкә, күгәрчен, ала карга – 4, аккош, тутый кош, чебеш – 3, карлыгач, козгын, бүдәнә, карчыга, тартар, тилгән – 2, тургай, тукран, сыерчык, бөркет– 1 фразеологизм барлыгы ачыкланды.

Тикшерү нәтиҗәсе тагын шуны да күрсәтте:

1) йорт кошлары атамасы (тавык, әтәч, каз) белән ясалган фразеологизмнар 43% тәшкил итә. Бу адәм баласының әлеге кошлар белән тыгыз бәйләнештә булуын раслап тора;
2) татар халкы уңай төсмерне белдерү өчен, сандугач һәм карлыгач кебек кошларга; ә тискәре сыйфатларны тасвирлау өчен, тавык, чыпчык, карга кебек кошларга мөрәҗәгать итә;
3) татар телендә экзотик кош атамалары белән ясалган фразеологизмнар юк дәрәҗәсендә. Бу халыкның экзотик кошлар белән бәйләнешнең тыгыз булмавы һәм әлеге кошларның яшәү рәвеше, холкы белән таныш түгеллеге белән аңлатыла;
4) Кош атамалары кергән ике компонентлы тотрыклы сүзтезмәләр өч, дүрт компонентлы фразеологизмнарга караганда шактый күбрәк. Шулай ук биш һәм аннан да күбрәк компоненттан торган фразеологизмнар да очрады.

Татар телендә кош компонентлы фразеологик берәмлекләрне өйрәнү буенча эшләнгән хезмәтләр юк диярлек. Бу тема буенча кызыклы тикшеренүләр алдагы елларда да дәвам ителер дигән ышанычта калабыз.

*Файдаланылган әдәбият:*

1. Исәнбәт Н.С. Татар теленең фразеологик сүзлеге. Ике томда. I том – Казан, Татар.кит.нәшр., 1989. 495бит;
2. Исәнбәт Н.С. Татар теленең фразеологик сүзлеге. Ике томда. II том – Казан, Татар.кит.нәшр., 1990/ 365бит;
3. Йосыпов Р.Г. Татар һәм рус телләре фразеологизмнарының үзара нисбәте.- Фәнни Татарстан, 2016. №3:
4. Сафиуллина Ф.С. Татарча-русча фразеологик сүзлек. Казан: Мәгариф.

## БЕЛЕМ АЛУЧЫЛАРДА БАЛАЛАР ӘДӘБИЯТЫ КИТАБЫНА КЫЗЫКСЫНУ УЯТУ (АЙДАР ХӘЛИМ ИҖАТЫ МИСАЛЫНДА)

*Галимуллина Гөлчәчәк Минхарис кызы,*
*Яр Чаллы дәүләт педагогия университетының 5 курс студенты*
*Фәнни җитәкче: Мөбәрәкшина Илзирә Ильяс кызы,*
*филология фәннәре кандидаты, доцент*

Теманың актуальлеге. Татар әдәбиятында заман шаукымына иярмәгән, кыйбласына тугрылык саклаган, әсәрләреннән зыялылык өртелеп торган әдипләр төркеме бар. Халык язмышы, милләт язмышын иң югары кыйммәт дип таныган мондый әдипләр арасында Айдар Хәлим (Борис Нәҗметдин улы Хәлимов) лаеклы урын алып тора.

Айдар Хәлим 1942 елның 1нче гыйнварында Башкортстан Республикасының Миякә районы Бәләкәй (Рече) Кәркәле авылында укытучы гаиләсендә туа. А.Хәлим тормышны төрле яктан күргән, төрле өлкәләрдә эшчәнлек күрсәткән тәҗрибәле шәхес. Аның азатлыкка омтылу, каршылыкларны җиңеп чыгу, кыйбласына тугрылык саклау кебек сыйфатлары Түбән Кама шәһәрендә нефть химиясе комбинаты төзелешендә эшли башлагач ук ачык чагыла башлый.

Айдар Хәлим татар шигърияте, татар прозасы, татар публицистикасы һәм татар әдәби-эссеистик тәнкыйте өлкәләрендә зур активлык белән эшли. 2003 нче елда әдип Татарстан Язучылар берлегенең Гаяз Исхакый исемендәге премиясе лауреаты булуга ирешә. Хәзерге вакытта Татарстанның Яр Чаллы каласында яшәп иҗат итә. Әйтергә кирәк, иҗатының үзенчәлекләре, идея-эстетик кыйммәте, бүгенге әдәбиятта тоткан урыны А.Хәлимнең үзе тарафыннан да тикшерелә. Мәсәлән, балалар шигъриятендә “Орчык-малай Биктырыш” поэмасының ролен өйрәнгән хезмәте шундыйлардан санала ала [4]. Әдипнең балалар өчен язылган хикәяләре үсмерлек чорына кереп баручы балаларны изгелек һәм яхшылык, милли хәтер, җан сафлыгы кебек төшенчәләр белән кызыклы, шул ук вакытта уйланырга этәрә торган формада таныштыра. Татар җанын, татар рухын тоеп яши һәм эшли торган балалар тәрбиләүче мондый әсәрләрне фәнни өйрәнү – бүгенге чорда актуаль проблема булып тора.

Теманың өйрәнелү дәрәҗәсе. А.Хәлим иҗаты әдәби җәмәгатьчелек тарафыннан игътибарсыз калмый, аның тормыш юлы һәм иҗаты олпат галимнәр, язучылар тарафыннан өйрәнелә. Мәсәлән, аның иҗатына югары бәя бирүчеләрдән, “милләт каһарманы” дәрәҗәсенә күтәрүчеләрдән Ф.Бәйрәмова, М.Әхмәтҗановны атарга була. Әдип иҗаты шулай ук Р.Рахмани һәм Р.Сверигин кебек әдәбият галимнәре тарафыннан төрле аспектларда өйрәнелә.

Фәнни-тикшеренү эшенең максаты – Айдар Хәлимнең балалар әдәбиятында тоткан урынын һәм “Тал баласы Талхаветдин”, “Казанбаш”, “Кыяр караклары” әсәрләрен идея-эстетик аспектта анализлау.

Максатка ярашлы рәвештә, түбәндәге бурычлар билгеләнде:

1) А.Хәлимнең балалар әдәбиятында тоткан урынын билгеләү;

2) А. Хәлимнең әсәрләрендә әхлакый проблемаларның бирелеше һәм чишелешен күрсәтү;

3) А. Хәлимнең әсәрләрендә фәлсәфи проблемалар бирелешен ачыклау.

Тикшеренү объекты итеп А.Хәлимнең “Тал баласы Талхаветдин”, “Казанбаш”, “Кыяр караклары” әсәрләре алынды.

Тикшеренү предметы – әсәрләрдә күтәрелгән әхлакый һәм фәлсәфи проблемалар.

Кулланылган тикшерү методлары: тасвирлама, психологик, чагыштырма.

Эшебезнең гамәли әһәмияте анда тәкъдим ителгән материалның филология факультеты студентлары тарафыннан семинар дәресләргә, конференцияләрдә чыгыш ясарга хәзерләнгәндә кулланылу мөмкинлеге белән билгеләнә.

**Айдар Хәлим һәм балалар әдәбияты**

Балалар әдәбияты – гомуми әдәбиятның кызыклы да, катлаулы да бер өлеше булып тора. Нигездә игътибар олылар әдәбиятына бирелгән әлеге заманда балалар язучыларыннан олы талант, саф күңеллелек, фидакарь хезмәткә сәләтлелек таләп итә. Татар балалар әдәбиятын хәзерге вакытта үсештә, дип атарга була. Шәүкәт Галиев традицияләренең дә дәвамчысы Роберт Миңнуллин, Фәнис Яруллин, Ленар Шәех кебек шагыйрьләр, Галимҗан Гыйльманов, Нәкыйп Каштанов һ.б. проза осталары хисабына байый, үсә. Әмма Айдар Хәлимнең балалар өчен иҗаты бөтенләй башка калыпта, башка тел белән, башка идея-тематикаларны колачлап язылган. Икенче төрле әйткәндә, әдип балалар әдәбиятын, шул исәптән, дәреслекләрне дә милли рух тәрбиясенә хилафлык китергән, рус, Көнбатыш Европа әдәбиятына таянып язылган, бары көлке, сүз уйнатуга гына кайтарып калдырылган, һәм шуның белән бер бала тәрбиясенә генә түгел, гомумән, милләт үсешенә дә зыян китергән әсәрләрдән арындырырга чакыра. Алмашка әдәпле, инсафлы, югары әхлак сыйфатларын пропагандалаган, Габдулла Тукай традицияләрен дәвам иткән әсәрләр килергә тиеш, дип яза Айдар Хәлим. Аның үзенең әсәрләре – нәкъ әнә шундыйлар. Алар сан ягыннан күп түгел, әмма бу әсәрләр – татар рухы белән өртелгән булулары, иманлы буын тәрбияләүдә гаҗәеп зур потенциалы белән аерылып торалар.

Аның шигъриятендә сурәтләнгән балалар – ләззәт-бәхет, уен-көлке эчендә рәхәт көн күрүчеләр түгел, ә олылар тормышының авыр, аянычлы якларын үз җилкәләрендә бөтен тулылыгы белән татучылар. “Казлар көтүче малай турында баллада” (1968) – шуның ачык мисалы:

Бар җиһазы – киндер күлмәк, киндер ыштан,
Чебиләгән аяклары – нәкъ күн итек.
Кочаклаган да үз җирен иң җиткәнче,
Сүнгән сабый, – арыгандыр казлар көтеп [7, б.70].

Тулаем алганда, А.Хәлимне балачак дөньясына үтә житди каравы, баланың рухын юк-бар көлке белән алдамавы, бозмавы аерып тора. Р.Сверигин игътибар иткәнчә, “А.Хәлимнең алдагы зур ачышлары геройларның балачакларыннан, тормышның олы, каршылыклы дәрьяларына күчеп барган мәлләрен сурәтләү җирлегендә башкарылыр төсле. Бәлки, балачакта күңелләренә иман нурлары сеңгән нәниләребезнең өметләре олылар дөньясында яңадан-яңа күркәм яклары белән ачылыр дигән фаразыбыз авторның соңгы әсәрләрендә расланып килә. Аның аксакаллары да еш кына сүзнең бик яхшы мәгънәсендәге сакаллы сабыйлар булып чыга, ягъни геройларның күбесе, олыгайгач та, сабыйлыкның кайбер матур сыйфатларын югалтып бетермиләр. Гүя автор өчен кеше гомере – җанда гомер буе дәвам иткән балачак” [10].

Иҗаты гражданлык, милли үзаң белән сугырылган А.Хәлим балалар әдәбиятында да сизелерлек эз калдыра. Таланты аңа төрле жанрларга мөрәҗәгать итәргә мөмкинлек бирә,

әдип шул мөмкинлекне иманлы буын тәрбиясе өчен файдалана. Ул әкият-поэмалар, балладалар, шигырьләр иҗат итә. Аларның стиле, теле аерылып тора, әмма берләштерүче үзәк тә бар: аның геройларын эш сөючәнлек, дуслыкның кадерен белү, милли рух кебек сыйфатлар берләштерә. Эш дәвамында шагыйрьнең бер генә әсәрендә дә икеле алучы, ялкауланучы, куштанланучы, хәтта телевизор караучы бала образы очрамады. Аның әсәрләрендәге балалар олыларга хас проблемаларны хәл итәләр, олылар тормышы белән яшиләр.

**“Тал баласы Талхаветдин” әсәрендә әхлакый һәм фәлсәфи катлам**

Әсәр тартмалы композициягә корылган. 19 хикәя бер-берсе белән тыгыз бәйләнеп тулы бербөтенгә оеша. Әсәрнең һәр бүлеге татар милләтенең, татар халкының тарихын, үсеш чорын тасвирлый. Аның структурасы түбәндәгедән гыйбәрәт:

- “Болыттан туган тал баласы” хикәясе кешелекнең барлыкка килүен тасвирлый;
- “Таллар шатлыгы” – башка милләтләр белән бер рәттән татар милләтенең формалашуын күрсәтә;
- “Төн һәм көн” – әйләнә-тирәбездәге һәр нәрсәне бар иткән, мәңгелек мәрхәмәт, изгелек һәм рәхмәт иясе – Аллаһы Тәгалә;
- “Һавалар нигә зәңгәр?” – татар халкы кичергән авырлыклар аларга аерым хәтер бүләк итеп, аларны беркайда да адашмас һәм беркайчан да бер-берсен ташламас нәселгә әверелдергән;
- “Арбадагы сәяхәт” – сабырлык һәм күп көч куеп кына нәтиҗәгә ирешеп булу турында;
- “Кем акча югалтты” – татар халкы дин тыелган заманаларда яшәсә дә, үз диненнән баш тартмый. Безнең изге китабыбыз “Коръән Кәрим”ебез бар;
- “Йөзү остасы” – яхшы гамәлләр кылу өчен тирән акыл, тырыш кул белән теләк кенә кирәк;
- “Диңгез ярында сөйләшү” – татар милләте кыйналып җиңәргә өйрәнә;
- “Уенчык кибетендә” – бәхетле булу өчен кыйбатлы уенчыклар да, таш диварлар да кирәкми, бары тик Ватаның, туган йортың, якыннарың янында булу кирәк;
- “Беренче намаз” – бар нәрсәне барлыкка китергән өчен без Аллаһы Тәгаләгә рәхмәтебезне намаз аша җиткерәбез;
- “Кискән саен үсә торган тал-металл” – “без мәңге үлемсез. Без – тал-татарлар! Без киселгән җирдән генә түгел, сагынудан җиргә тамган күз яшеннән дә үсәбез!”;
- “Үзәгеңне сакла балам!” – сабырсыз, ялкау булсаң эшнең нәтиҗәсе аянычлы була;
- “Боз сөңгесе, Күргән һәм Күрмәгән” – “иртә торсаң ит пешә, соңга калсаң бит пешә”;
- “Кайсы тәмлерәк?” – һәр кәвемнең, һәр кешенең яраткан ризыгы була. Татарларның төп ризыклары – бәрәңге һәм икмәк;
- “Күрше хакы” – безнең якыннарыбыз, дусларыбыз нинди генә милләт вәкилләре булмасын без аларга яхшылык кына эшләргә тиеш;
- “Авыл бетмәячәк!...” – авылларның яшәешендә татар милләтенең киләчәге;
- “Булмаганны чүпли” – кешеләрнең булганнары һәм булмаганнары да бар;
- “Туган тел” китабы” – татар милләтенең горурланырдай бөек шәхесләре, туган телләре – татар телебез бар;
- “Шифаханәдә” – безнең үз кануннары булган саф, пакь динебез бар;

Әсәрнең төп герое тал баласы Талхаветдин символ дәрәҗәсенә җиткерелеп, милләтнең киләчәге кебек мәгънәви эчтәлекне үзенә беркетә.

Бу әсәрендә А.Хәлимнең милли концепциясе үзенчәлекле итеп ике катламда бирелгән:

1) Һәр хикәядә Талхаветдиннең төрле сыйфатлары ачыла бара, шулар аша язучы татар милләтендә күрергә теләгән сыйфатларны барлый: намуслы, бердәм, юмарт, батыр,

эшлекле, көчле, тырыш, сабыр, түзем, игътибарлы, нечкә күңелле, оялчан, бәхетле, гөнаһсыз, акыллы, иманлы;

2) Һәр хикәядә автор милли идеянең мәгънәви эчтәлеген ача: тарих, намус, Аллаһы Тәгалә, тырышлык, хәтер, авыл, Коръән Кәрим, милләт, акыл, иман, ватан, туган тел, туган җир, туган йорт, хезмәт, ата-ана;

Әлеге әсәрнең кызыклы ягы тагын шунда, автор балаларга фикерне әйтеп бетерми, балада сорау туу мөмкинлеге, уйлану өчен җирлек калдыра.

**“Казанбаш” поэмасының иде-эстетик кыйммәте**

Поэма бер-берсе белән тыгыз бәйләнеп тулы бербөтенгә оешкан 8 бүлектән гыйбәрәт. Әсәрнең һәр бүлеге татар милләте, татар халкының тарихын барлауга һәм шуңа бәйле горурлык хисләре белән януга корылган.

Аның структурасы түбәндәгедән гыйбәрәт:

I бүлектә поэма герое балаларны кызыксындырып үз балачагына сәяхәткә чакыра, дуслары Камил һәм Вәкил белән таныштыра. Төп герой “кишер карагы” кушаматына ия булган биш яшьлек, гаиләдә төпчек бала. Малайлар бик тату яшиләр, аларны бер хәсрәт берләштерә:

“Бер кашыктан ашап үскән әхири-дусларыбыз,
Әтиләр сугышта үлеп, югалткач хушларыбыз,
Газиз әнкәйләребез канаты асларында
(Алар безгә бирә иде кабасы ашларын да!)
Без ике ятим гаилә, бүлешеп ярты-ярым,
Яшибез бер оя булып – ястыклар гына аерым” [5, б.4].

II бүлектә А. Хәлим игътибарын туган якның матурлыгына, хозурлыгына юнәлтә:

“Кырылган инешең буйлап озатып килә таулар,
Гүя таулар үзәннәрне җитәкләп барган баулар.
Уралтавыбыз бай ташка – чакматаш, якутташка,
Айташ, майташ, гәрәбәташ, беләүташ, тактаташка”
“Менә урманга да җиттек. Саумы, әй, серле урман!
Үзең түшәк, үзең мендәр, үзең үк йомшак юрган!” [5, б.8]

III бүлектә исә А. Хәлим тарихка мөрәҗәгать итә.

“Монда карттәйләр ук юнган, тире иләп, теккән садак,
Яндырып күмер, эретеп тимер, ясаган дага, кадак;
Көтүләр көтеп, җәйләүдә мал чалып, ит каклаган,
Сәнәк саплап, кием баплап, дошманнан ил саклаган;
Монда карт инәйләребез күренми илгә артык,
Гөбердәтеп сыер сауган, оеткан төче катык;
Каймак язып, май таскыган, кайнаткан ачы корыт,
Ак гөбедә кымыз пешкән таңнардан иртә торып...” [5, б.10].

IV, V бүлекләрдә урман үзенең бар матурлыгы белән сурәтләнә. Урман – ниндидер бер сихри көчкә ия. Аның һәр агачыннан, һәр яфрагыннан җан өркеп тора. Табигатьнең, туган якның матурлыгына сокланып, яшел үләндә тәгәрәгәндә кинәт кенә балаларны “нифте базы”на ташлаучы Казанбашлар барлыкка килә.

Ләкин “кишер карагы” моңа юл куймый, ул бөтен авыл халкын бу “гыйфритләргә” каршы көрәшкә чыгара:

“Артка боролып карасам – күтәрелгән бар авыл:
Кемдә уклау, бәләк, җәмкә, кисәүагач, сыргавыл,
Кемдә чалгы, кемдә көрәк, тырма, йә шунда сәнәк,
Тотып колган, чыккан юлга – коралланганнар һәлак!” [5, б.22].

Әлеге сюжет VI-VII бүлекләрне тәшкил итә.

VIII бүлектә исә автор чынбарлыкка кайта. Киләчәктә “күктә янсын якты кояш, җирдә – илһам утлары, нифте даулап, бомба ташлап, үтмәсен самолетлар” [5, б.26] дигән теләк белән әкиятен тәмамлый.

Гомумән алганда, поэманың сюжет-композицион яктан төзелеше үзенчәлекле: әкият эчендә әкият рәвешендә язылган.

I әкиятнең нигезенә Казанбашлар турындагы риваять салынган. Имеш, Ишембай якларыннан башларына казан кигән кешеләр килеп, балаларны тотып алалар, җир мае базларына салалар да, каннарын сыгалар икән.

Моның нигезендә II әкият барлыкка килә. Ул Вәкил белән Камилнең лирик геройны алдавыннан башланып китә. Беркатлы авыл баласы, үзенең туган нигезе, милләттәшләре өчен борчылып, бөтен авыл халкын шул “бала ашаучылар”га каршы күтәрә. Ләкин дөреслек ачылгач та, лирик “мин” борчылмый, киресенчә, анда горурлык хисе уяна, чөнки ул үз милләтенең киләчәге өчен көрәшердәй шәхес булып үсә.

Әлеге поэмада автор сугышка, тарихка бала күзлегеннән бәя бирә. Чөнки татар халкының үсеш дәверендә басып алулар, сугышлар күп булган, ләкин татар халкы каршы тора алырдай зур һәм көчле милләт. “Казанбаш” поэмасының төп герое да милләтебезнең киләчәге өчен көрәшергә өнди:

“Әйдәгез, тотып тастымал, аңарга каршы барыйк,

Егып үзен, бәйләп күзен, безнең коега салыйк!” [5, б.24].

Ул сугыш фаҗигасен татыган, ләкин шул ук вакытта бала булып кала алган герой. Балаларга хас барлык сыйфатларда: шаян, тәвәкәл, самими, хыялый, киң күңелле, кызыксынучан, игътибарлы, куркак һәм шул ук вакытта батыр, беркатлы, авылҗанлы, тырыш, шул ук вакытта акыллы, баһадир, милләтенең, нәселенең үткәнен белүче көчле һәм горур образ.

Элеге сыйфатлар лирик “мин”не символ дәрәҗесенә күтәрә һәм милләтнең киләчәге дигән мәгънәви эчтәлекне үз эченә ала. Автор лирик герой аша балаларда нинди хис тәрбияләргә икәнен ачып бирә. Ул милләтнең киләчәген татар халкының тарихын белгән, ана телен хөрмәт итүче, халкыбызнең традицияләрен саклап килүче – татар авылларының киләчәге өчен көрәшә алучы, үзенең татар милләтенең бер вәкиле булуы белән горурланучы шәхесләрдә күрә.

“Казанбаш” поэмасында татар халкының бөек шагыре, Г.Тукай традицияләрен тоемларга була. Әсәрнең сюжет-композициясе, образлар бирелеше, идея-тематикасы Г. Тукайның “Шүрәле” поэмасына охшаш.

Тарихи яссылыкта карасак әлеге әсәрдә А. Хәлимнең азатлык һәм табигать белән кеше бердәмлеген яклап чыгуы ачык күренә. “Казанбаш” образын ике яклап ача:

- беренчедән ул “Казанбашларны” немец сугышчылары белән чагыштыра: “Әтиләребез, нәкъ шул казан сыман “каска” кигән немец-фашистларына каршы сугышта һәлак булганга, күрәсең, бу “Казан-баш”лар безнең күз алдыбызга басканчы дошманнар рәвешендә киләләр иде” [5, б.2].

- икенчедән “Казанбаш”лар образы ярдәмендә А. Хәлим чорның рухи фаҗигасе – кеше белән табигать гармониясенең җуелуы турында сөйли:

“Шәпкорсаклар, капкорсаклар – корсакларында боргыч.

Шуннан нифте атыла ди җир астыннан суыргач.

Табигатьне җен ясый, ди, шакшы нифте базлары –

Дегет эчеп карая, ди, ап-ак авыл казлары!...” [5, б.16].

Поэманың тагын бер үзенчәлеген әйтеп үтәргә кирәк:

“Мин бүген дә сабыйларны казан башлардан саклап,

Утырам Мендәрле Күлда тау яклап – урман яклап.” [5, б.26]

– дигән строфалар төп герой һәм автор арасында параллель уздырырга мөмкинчелек бирә. Чөнки А. Хәлим татар милләте, ана телебез – татар теле өчен янып-көюче шәхес.

Шул рәвешле, “Казанбаш” поэмасында балачак, табигать, авыл матурлыгына фаҗигале милләт язмышы каршы куела. Дуслык, тугърылык, бердәмлек, горурлык, мәхәббәт, тынычлык кебек кыйммәтләр поэманың үзәгенә ята.

**“Кыяр караклары” әсәрендә әдәп-әхлак мәсьәләләре**

Айдар Хәлимнең күп кенә әсәрләрендә бала образы мөһим роль башкара. “Кыяр караклары” әсәре үсмерлек чорына кереп баручы балаларны милли хәтер, җан сафлыгы, гаделлек кебек төшенчәләр белән кызыклы, уен формасында таныштыра.

Әсәрнең төп геройлары, Шәрифҗан картның сугыш турындагы маҗараларын тыңлап үскән “кыяр караклары”, кыяр басуына һөҗүм итү планын коралар:

“Менә әле дә кыярлар янына кермәс борын
Безне танымасын, диеп буйыйбыз биткә корым.
Без Һинд Чингачгук сыман, башларга тасма бәйләп,
Ук-җәяләребездән аркага йөкләп корал,
Һәркайсыбыз кыяр өчен үләргә әзер тора” [6, б.5].

Шәрифҗан карт исә Мисыр мәкаме белән изге гамәл – намаз уку белән мавыгып киткән арада малайлар тавыш-тынсыз капшаштырып, кыярларны уятып изү аша күлмәкләренең эченә озаталар, юллары уңса күлмәк эченә утыз биш кыяр сыя.

Шәрифҗан карт әлеге гамәлләре өчен малайларны ачуланмый, чөнки аларны әлеге адымга барырга шушы чор вакыйглары мәҗбүр итә, алар бит ачлык чоры балалары: “Изү ачык. Бил буыла. Ул, бусаң да буш була.”. Алай гына да түгел балаларны яраткан агалары моңа үзе өйрәтә.

Шәрифҗан карт, әлеге әсәрдә гомумкешелек сыйфатларына ия булган татар карты буларак бирелә:

“Яхшы кеше ул, әлбәтта. Ачык җирдә җил кумас.
Йомшак күңелле. Безне һич эш өстендә борчымас.
Гади түгел безнең бабай. Брусилов әрмәсендә
Ул ярманнан яра ала Сандомир тирәсендә” [6, б.9].

Әлеге вакыйгалар әсәрне ике төп өлешкә бүлергә ярдәм итә:

I – уен өлеше: әлеге өлешкә “чингачгук” малайларының балачагы, кыяр басуын басып алу операциясен әзерләүләре керсә, II – чынбарлык өлешендә Шәрифҗан картның сугыш чоры сурәтләнә.

Айдар Хәлим балачакны “ярый-ярамый йозагы” дип атый, бары тик балачакта кеше дөньяның тәмен татып, ләззәтләнеп, керсез хыялларда яши:

“Әй, бала чак! Эзләр салып, ләззәтле газап белән
Ярый-ярамый йозагын ачасың кадак белән.
Көнен-төнен ак хыялда чикләрнең чиген узып,
Чабасың хәтер атларда – шунда табасың кызык ” [6, б.10].

Балаларның уенын сурәтләү өчен кулланылган сугыш лексикасы (“сайладык позиция”, “кайтты разведка”, “зур походка җыенган гаскәр сыман”, “командир”, “шуышабыз пластунча”, “патрон” һ.б.) безгә балалар һәм Шәрифҗан карт арасында параллель уздырырга ярдәм итә. Балаларга – кыяр кадерле булса, Шәрифҗан картка сугыш вакытында – туган җире кадерле була. Туган ягының саф һавасын, туфрактан бөркелгән кайнар дымын, хәтта әрем тәмен дә сагына ул:

“Саумы, әй, кыяр туган!...
Сөекле хуш исләреңне кем генә иснәп туйган!
Пешенгән туфрак. Яшел җил. Үтә рәт араларын
Кайнар дым. Яшь кыяр тәме... әллә нәрсәләр тагын!.. ” [6, б.8].

Сугышта Шәрифҗан ага һәм башка солдатлар туган ягы өчен үз гомерләрен, көч һәм сәламәтлекләрен җәлләмәгән кебек үк малайлар да “һөҗүм” вакытында “кыяр өчен үләргә әзер тора”.

Әлеге ике өлешне берләштерүче булып туган як табигате, аның матурлыгы билгеләнә. Баш очында кояш та җырлый, чыпчыклар оча пырлап, хәтта гади кыярны да автор “су белән кояш бәбәе” дип атый.

Айдар Хәлимнең балалар иҗатына хас бер үзенчәлеге әлеге әсәрендә дә чагылыш таба. Милләтпәрвар язучы буларак ул әлеге әсәрендә көлкеле һәм мавыктыргыч сюжет сызыгына киң, тирән мәгънә сала.

“Дәүләтең бай да – малың юк, акчаң да юк.

Шуклыктан урлыйсың кыяр – яшелчә бакчаң да юк” [6, б.10] юллары авторның сәясәткә, милләтенә булган мөнәсәбәтен ачык чагылдыра. А. Хәлимнең нинди генә әсәрен алып карасак та алар татар рухы белән өртелгән булулары, иманлы буын тәрбияләүдә гаҗәеп зур потенциалы белән, милли концепция салынуы аерылып торалар.

Әдәбиятыбызда тәнкыйтьчеләр тарафыннан да, галимнәр тарафыннан да аз өйрәнелгән өлкәләр, иҗатлары җитәрлек дәрәҗәдә тикшерелмәгән каләм ияләре бар. Айдар Хәлим – шундыйларның берсе. Дөрес, фикердәшләре-каләмдәшләре аның иҗатына гомуми бәя бирәләр, кыю фикерле һәм сынмас рухлы булуы тәнкыйтьчеләр тарафыннан да ассызыкланып кителә. Әмма әдипнең иҗат лабораториясе тәфсилләп тикшерелмәгән, әсәрләренә төпле анализ әлегәчә ясалмаган. Бигрәк тә әдипнең балалар әдәбияты өлкәсендәге иҗатында ак таплар күплеге күзгә ташлана.

Әлеге фәнни-тикшеренү эше кысаларында без Айдар Хәлимнең балалар өчен язылган әсәрләренең идея-тематик эчтәлеген әхлакый һәм фәлсәфи яктан өйрәнүне максат итеп куеп, әдипнең хәтта балалар өчен язган әсәрләренең дә күп катламлы, төрле дәрәҗәдә әзерлекле укучыга юнәлгән булуы, хәтта, әйтер идек, интеллектуаль проза дәрәҗәсендә торуын ачыкладык. Беренче карашка, аның балалар өчен язган әсәрләре кызык һәм мавыктыргыч рәвештә язылган булса да, аларга киң, тирән мәгънә салынган. Әсәрләренең төп геройларының әйләнә-тирә белән танышуын күзәткән укучы алдында татар тарихы, татар характеры, татар язмышы, татар дине – мөселман дине турындагы зур картина пәйда була. Ул нигездә әхлакый һәм фәлсәфи катламнар аша гәүдәләндерелә.

Айдар Хәлим өчен иң югары кыйммәтләр булып хезмәт сөючәнлек, тырышлык, белем алуга омтылыш, Ватанга мәхәббәт, ата-ана һәм күрше хакын хаклау кебек сыйфатлар торалар. Әлеге сыйфатлар герой характерын ачучы сыйфатлар буларак кына түгел, ә милли характерның үзәген тәшкил итүче сыйфатлар булып аңлашылалар. Айдар Хәлим шигъриятендә дә, проза жанрында иҗат ителгән әсәрләрендә дә балалар һәм олылар дөньясы кискен рәвештә бүленми. Аның каһарманнары олыларның мәшәкатьле авыр тормышы эчендә яшиләр, фәлсәфи фикер йөртәләр, яшәү-яшәеш турында уйланалар, хәлдән килгәнчә, олыларга ярдәм күрсәтәләр.

Кыскасы, Айдар Хәлимнең балалар әдәбияты өлкәсендәге эшчәнлеге аерым үзенчәлекләргә ия. Ул балаларны олылар белән тиң күреп, алар белән олылар телендә сөйләшә. Аларда эш сөючәнлек, Ватанга мәхәббәт, өлкәннәргә ихтирам кебек әхлак сыйфатларын тәрбияләүне төп максат итеп куя. Аның әсәрләре мәктәп яшендәге балаларга аталып язылып, фәлсәфи тирәнлеге белән олыларны да таң калдырырлык әсәрләр буларак бәяләнә ала. Әмма игътибарны икенче юнәлешкә дә бирәсе килә. Соңгы елларда Федераль дәүләт белем бирү стандартлары таләпләренә нигезләнеп язылган яңа дәреслекләр дөнья күрде, әмма аларда Айдар Хәлимнең “Орчык-малай Биктырыш” әкият-поэмасы да, “Тал баласы Талхаветдин” хикәяләр җыентыгы да урын алмаган. Шәхсән, безнең уйлавыбызча, аның бөтен әсәрләредә моңа лаек. Әлбәттә, рус телле балаларга татар рухын аңлавы да, әсәрләрне укуы да катлаулы булыр иде, әмма татар мәктәпләре өчен язылган дәреслекләрдә Айдар Хәлимнең әлеге әсәрләре урын алырга лаек.

*Кулланылган әдәбият исемлеге:*

1. Даутов, Р.Н. Әдипләребез: биобиблиграфик белешмәлек: 2 томда: 2 том / Р. Н. Даутов, Р. Н. Рахмани. / – Казан: Татар. кит. нәшр, 2009. – Б. 564 – 568.

2. Заһидуллина, Д.Ф. Татар әдәбияты: Теория. Тарих. Д.Ф. Заһидуллина, Ә.М. Зәкирҗанов, Т.Ш. Гыйләҗев, Н.М. Йосыпова. / – Казан: Мәгариф, 2006. – 319 б.

3. Хәлим, А. Тал баласы Талхаветдин: балалар өчен нәни хикәяләр /А. Хәлим. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. – 48 б.

4. Хәлим, А. Татар балалар шигърияте һәм “Орчык-малай Биктырыш” (бүгенге балалар шигъриятенә фәлсәфи күзәтү) / А. Хәлим. – Чаллы: ҖЧҖ Диамант, 2010. – 268 б.

5. Хәлим, А. Казанбаш: төсле нәфис чыгрылыш /А. Хәлим. – Казан: «Идел-пресс», 2014. – 29 б.
6. Хәлимов А.Н. Кыяр караклары / А. Хәлим. – Казан: «Раннур» нәшрияты., 2002. – 14 б.
7. Хәлим, А. Тилергән сирень: шигырьләр, балладалар / А. Хәлим. – Казан: Рухият, 2003. – 608 б.
8. Әхмәтҗанов, М. Милләт каһарманы / М. Әхмәтҗанов // Мирас. – 2000. – № 8. – Б. 54 – 62; №11. – Б. 94 – 98.
9. Бәйрәмова, Ф. Ак һәм кара көрәше / Ф. Бәйрамова // Казан утлары. – 2001. – № 12. – Б. 119 – 128.
10. Сверигин Р. Кыйблага кайту. – URL: http://kazanutlary.ru/?p=22716; мөрәҗәгать итү датасы: 10.05.2017.

## МАТБУГАТ ЯЗМАЛАРЫНДА СӨЙЛӘМ ХАТАЛАРЫ

*Закирова Динә Айрат кызы, 10нчы сыйныф укучысы*
*Фәнни җитәкче: "Ядегәр авылы Г.Г.Гарифуллин исемендәге урта гомуми белем бирү мәктәбе"нең югары квалификацион категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы Фатыйхова Люция Шархинур кызы*

Тел – рухи тормышыбызның аерылгысыз өлеше. Сөйләмнең нинди булуы кешенең аң-белеме, фикерләренең ни дәрәҗәдә икәнен күрсәтергә ярдәм итә. Һәр кеше сөйләм культурасына ия булырга тиеш. Сөйләм культурасы үзеннән-үзе генә килми, аны сөйләмеңә һәрчак игътибар итү нәтиҗәсендә генә камилләштереп була.

Сөйләм, аерым таләпләргә җавап биргәндә генә, тыңлаучыга һәм укучыга аңлаешлы, үтемле була. Алар түбәндәгеләр: сөйләм төгәл, аңлаешлы, саф, чиста, җыйнак, аһәңле булырга тиеш. Мондый сөйләмгә без мәктәптә өйрәнәбез. Радио һәм телевидение, газета-журналлар да матур һәм дөрес сөйләмгә өйрәтергә тиеш. Мин буш вакытларымда газеталар укырга яратам. Кызганычка каршы, массакүләм мәгълүмат чараларында сөйләмебезне бозу очраклары еш күзәтелә. Туган тел дәресләрендә сөйләм культурасына куела торган таләпләрне өйрәнгәч, мин газеталардагы язмаларны игътибарлырак укый башладым. Сүзне урынсыз куллану, аларның үзара табигый бәйләнеш нормаларын, җөмләдә урнашу тәртибен бозу, рус теле өчен хас формаларны татар теленә күчереп кую күренешләре сөйләмгә зыян китерә. Телебез матурлыгын югалта бара. Бу тема татар телен ээзәрлекләү, кимсетү һәм мәктәпләрдә мәҗбүри укытуны тыю шартларында бик актуаль.

Эшемнең төп **максаты:** матбугат язмаларында сөйләм культурасы таләпләренә туры килмәгән очракларны табып, аларны төзәтү юлларын күрсәтү. Максаттан чыгып, **бурычлар да** билгеләнде: матбугат язмаларында күзәтелгән хаталарны анализлау; туган телне саклап калуга үземнән өлеш кертү.

**Өйрәнү объекты:** "Акчарлак", "Ватаным Татарстан", "Ирек мәйданы", "Татарстан яшьләре", "Хезмәт даны" газеталары.

Сөйләмне һәркем аңларлык итеп оештыра белү, әйтергә теләгән фикерне тулысынча төшендерә алу өчен, берничә шартны үтәү таләп ителә. Беренчедән, җөмлә төзек булырга тиеш, анда мәгънә буталуга, фикерне төрлечә аңлауга юл куярга ярамый. Ике төрле аңлауга китерә торган җөмләләр әледән-әле матбугат битләрендә очрап тора.

Мәсәлән, "**22 яшьлек авылның** сөлектәй егете чит җирләрдә башын сала". ("Хезмәт даны" №12, 2018нче елның 16нчы феврале, 3нче бит) дигән җөмләдә автор 22 яшьлек егет дип әйтергә теләгәндер, ләкин җөмлә төзелеше буенча 22 яшьлек авыл дип аңлашыла. "Авылның **22 яшьлек сөлектәй егете** чит җирләрдә башын сала" дисәк, мәгънә буталуга урын калмас иде.

“**Аллергия кебек бу заманда** тирә-юньне басып киткән чирләр дә ишетелми”. (“Татарстан яшьләре”, 1нче февраль, 2018) дигән җөмләдә автор сүзләрнең урынын, аларның бәйләнешен кат-кат тикшермәгән. Ул аллергия кебек заман дип түгел, аллергия кебек чирләр дип әйтергә теләгән, минемчә. “Бу заманда **аллергия кебек тирә-юньне басып киткән чирләр дә** ишетелми” дисәк, дөресрәк булыр иде.

“Бер газетадан “**Иң беренче кеше** белән яшәүче хайван – ул этләр” дигән җөмләне укыдым да көлеп җибәрдем” (“Татарстан яшьләре!, 1нче март, 2018нче ел, 6нчы бит) “Кеше белән яшәүче **иң беренче хайван** эт икәнен әйтергә теләгән”,- дип яза автор.

“Ике ел узгач, мәктәптә укытучылар җитмәгәнлектән, этиләрне **кире Наратлыга** чакырганнар”. (“Татарстан яшьләре”, 7нче март, 2018нче ел, 14нче бит) Кире сүзеннән соң Наратлы сүзе тора һәм ул кире Наратлы дип аңлашыла, ә чынлыкта сүз кире җибәрү турында бара, шуңа күрә җөмләне башкача төзергә кирәк: “Ике ел узгач, мәктәптә укытучылар җитмәгәнлектән, этиләрне Наратлыга **кире чакырганнар**”.

“Ишекне ачып, бер адым атлауга ук **кире өйгә** кайтасы килә башлады: салкын җил бит алмаларын умырып-умырып тешли иде” (“Акчарлак”, 12нче гыйнвар, 2018нче ел, 13нче бит) Бу җөмләдә кире сүзе кайтасы сүзен ачыклап килә, шуңа күрә кире сүзен өйгә сүзеннән соң куярга кирәк.

Икенчедән, сүзләрдә бер үк бәйләүче чараның кабатланып килүе җөмләне авырлаштыра, язма телне төссезләндерүгә алып бара, әйтергә теләгән фикерне тоныкландыра. “Авылыбыз**ның** күп ярәшкән парлары үзләре**нең** бүгенге бәхетле көннәре**нең** бер мизгеле өчен “Бостон”га бурычлы” җөмләсендә (“Татарстан яшьләре”, 31нче август, 2017нче ел, 6нчы бит) иялек килеше кушымчасы 3 тапкыр кабатлана. Җөмләне “Авылыбыздагы күп ярәшкән парлар бүгенге бәхетле көннәренең бер мизгеле өчен “Бостон”га бурычлы” дип үзгәртсәк, дөресрәк булыр иде.

Бер үк бәйләүче чара, әгәр ул тыңдаш кисәкләр янында булмый икән, шул ук җөмләдә кат-кат алынса, сөйләмнең эзлекле агышын боза, фикер ачыклыгы югала.

Өченчедән, туган тел үзенчәлеген искә алмыйча төзелгән җөмлә аңлаешлы булмый. “Бу вакытта безнекеләр **Ленинград астында** дошманны кысрыклый башлаган була инде”(“Акчарлак”, 1 март, 2018нче ел, 15нче бит) “Бу вакытта безнекеләр Ленинград янында дошманны кысрыклый башлаган була инде” дип язсак, җөмлә җиңел аңлашылыр иде. “Квадроциклларда ярышу өчен дә мәйданчык **хәл ителгән**”(“Татарстан яшьләре”, 31нче август, 2017нче ел, 3нче бит)җөмләсендә хәл ителгән сүзе урынына билгеләнгән сүзен кулланcак, уңышлырак булыр иде.

Сөйләм төгәл булсын өчен, әдәби нормаларны яхшы үзләштерергә кирәк. Матбугат язмаларында очраган сөйләм төгәлсезлекләре йөрәкне әрнетә.

Беренчедән, сөйләм төгәллегенә ирешү өчен, синонимикадан дөрес файдалана белү мөһим. “Элеккене **белмәүче** бүгенгенең кадерен **белми**”(“Татарстан яшьләре”, 22нче февраль, 2018нче ел, 5нче бит) җөмләсендә бер үк тамырдан ясалган сүзләр кабатлана. Бәлки, белми сүзе урынына **аңламый** сүзен кулланыргадыр.

“Миңа **сагышлану** халәте бик ошый, чөнки **сагышланганда**, кеше күп уйлый”(“Татарстан яшьләре”, 22нче февраль, 2018нче ел, 9нчы бит) җөмләсен “Миңа **сагышлану** халәте бик ошый, чөнки **бу вакытта** кеше күп уйлый” дип язу төгәлрәк булыр иде.

Икенчедән, бер үк сүз яки форма кабатланып килгәндә, аларның берсен алмашлык белән алыштыру отышлы. “**Умарталарның** караклыгына юл куймас өчен, төп бал вакыты беткәнче **умарталарга** ревизия үткәрәм”(“Ирек мәйданы”, 19нчы октябрь, 2017нче ел, 25нче бит) җөмләсендә кабатланып килүче сүзләрнең икенчесен **аларга** алмашлыгы белән алыштырырга мөмкин.

Өченчедән, җөмләдә тиешле урында тыныш билгесен куймау да сөйләмнең төгәлсезлегенә китерә.

“Бакча күршем Гөлфия аларны төрле төсләргә буяп, эченә уңдырышлы туфрак салынган иске машина шиннары эчендә үстерә” (“Татарстан яшьләре”,1нче март 2018нче ел,

15нче бит) Бу җөмләдә сүз  чәчәкләр үстерү турында бара.   Монда чәчәкләрне төрле төсләргә буяп дигән мәгънә аңлашыла.  Кагыйдә буенча  “төрле төсләргә буяп” сүзләре аерымланырга да тиеш, ләкин автор тиешле тыныш билгесен куймаган.  Минемчә, җөмлә болай төзелергә тиеш иде:  “Бакча күршем Гөлфия аларны  төрле төсләргә буялган,  эченә уңдырышлы туфрак салынган иске машина шиннары эчендә үстерә”.

“Ирем Илсөяр рульдә барганда үзе дә сөйләшми, янында тыкылдап барганны да яратмый”,  (“Татарстан яшьләре”, 1нче март, 2018нче ел, 14нче бит) җөмләсендә автор тарафыннан аерымланган хәлләр янында тыныш билгесе куелмаганлыктан,  җөмләнең төрен, ияләрне  билгеләү кыенлык тудыра. Илсөяр рульдә барганда сүзләре аерымланса, җөмлә -  иярченле кушма, (Ирем сөйләшми,  Илсөяр барганда) рульдә барганда аерымланса, гади (Ирем Илсөяр сөйләшми) булыр иде.

“Шәмсеҗиһан апам олыгайгач та ерак Сарманга килеп, улыбыз Рамилне карашты” җөмләсендә  олыгайгач та сүзләре өтер белән аерылса, ике төрле аңлау ихтималы калмас иде.

Кеше сөйләменең сафлыгына карап, сөйләүченең белем дәрәҗәсен һәм туган телгә мөнәсәбәтен билгеләп була. Башка тел сүзләрен катнаштырып сөйләү яки язу бу таләпне бозуга китерә.

Бүгенге көндә  сөйләм сафлыгына зыян китерә торган хаталарны халыкның ике телле булуыннан килә дип тә  әйтергә мөмкин. Рус һәм татар телләрендә эш итә торган татар кешеләре урынсызга рус сүзләрен кертеп сөйләшә, хәтта матбугат битләрендә  туган телгә хас булмаган әйтелмәләр, сүзтезмәләр кулланыла.

“Юлда торган **ГАИ** машинасын күрү машина йөртүчеләрне **дисциплинага** өйрәтсә, яшертен генә урнаштырылган приборларга күп очракта игътибар да итеп тормыйлар”(“Татарстан яшьләре”, 22нче февраль, 2018нче ел, 3нче бит)җөмләсендәге ГАИ сүзен -  ЮХИДИ, дисциплинага  сүзен тәртипкә дип язып була бит.

“Аш бүлмәсе, **“прихожий”** ишекләрен **минусласак**, яшәү өчен яраклы мәйдан – ике бүлмә кала”(“Акчарлак”, 1нче март, 2018нче ел, 10нчы бит) җөмләсендә “прихожий”, минусласак сүзләре сөйләм сафлыгын боза дип уйлыйм.

“Мәрхәмәтле, нечкә күңелле **генсегыбыз** Леонид Брежнев вакытында исә кытайлар белән дуслыгыбыз чәчәк атты”(“Татарстан яшьләре”, 15нче март, 2018нче ел, 4нче бит) җөмләсендәге генсегыбыз урынына гади генә итеп җитәкчебез дип язу уңышлырак.

“Бәлкем, энә шул **камералылыгы** белән туристларны җәлеп итәдер дә ул”(“Ватаным Татарстан”, 2нче март, 2018нче ел, 1нче бит)җөмләсендә камералылыгы сүзе аңлашылып бетмәде. Камералы булуы белән дисәк, гадирәк тә, аңлаешлырак та булыр иде.

Шул рәвешле, әдәби телебезнең үзендә сүз булып та, кирәксезгә алынма сүзләргә мөрәҗәгать итү белән килешеп булмый.

Халык юкка гына: “Кыскалыкта – осталык”,- димәгән. Шулай да газета-журналларда җыйнаклык таләбен боза торган очраклар җитәрлек. Бигрәк тә аерым сүз белән әйтергә мөмкин булганны берничә сүз белән бирү еш очрый.

“Ватаным Татарстан” газетасыннан мисаллар китерәсе килә: “Узган уку елында **минем күңелемдә** гомергә истә калырлык вакыйга булды”, “Бу **минем** күптәнге **хыялым** иде”, “Бу экспедиция **минем тормышымны** үзгәртте”(23нче март, 2018нче ел, 4нче бит), “Барысы да **минем Мәйсәрәмне** яратып кабул итте”(“Татарстан яшьләре”, 8нче март, 2018нче ел 18нче бит) җөмләләрендә I зат берлек сан кушымчасы алган исемнәр янында минем сүзе артык дип уйлыйм.

“Аннары **мин** ул әйберләрне **үземнең** рәсем сәнгат**ем**дә файдалана башладым”(“Татарстан яшьләре”, 22нче февраль, 2017нче ел, 8нче бит)җөмләсендә, минемчә,  үземнең сүзе кулланылмаса да, мәгънәгә зыян килмәс иде.

“Кеше бер үк вакытта **талантлы** шагыйрь, **талантлы** композитор, **талантлы** җырчы да була алмый”(“Татарстан яшьләре”, 1нче март, 2018нче ел, 8нче бит) җөмләсендә талантлы сүзе кабатланмыйча гына килсә,  җыйнаклык таләбе үтәлер иде дип уйлыйм.

Сөйләм,  аһәңле булганда гына, укучыны үзенә җәлеп итә ала. Татар теле ул үзенең төзелеше, байлык-хәзинәсе белән аһәңле, аны таба белергә, сөйләмдә шуңа омтылырга кирәк.

Кызганычка каршы, һәр сөйләм дә бу таләпкә җавап бирми, аһәңне боза торган кимчелекләр күзәтелә. Шуларның берсе – җөмләдә бер үк авазларның кабатланып килүе.

“Нәкъ шул чорда Малмыж һәм Киров мирасханәләрендә актарынып, Габдулла**ның** әни**се** Мәмдүдә абыстай**ның** нәкъ менә Сасна Пүчинкә**се** авылы**ның** указсыз мулла**сы** Мөхәммәтшакирга кияүгә чыгуы турындагы документлар**ның** эзенә төште” (“Татарстан яшьләре”, 31нче август, 2017нче ел, 11нче бит) җөмләсендә иялек килеше кушымчасы 4 тапкыр, 3нче зат, берлек сан тартым кушымчасы 3 тапкыр кабатлана. “Нәкъ шул чорда Малмыж һәм Киров мирасханәләрендә актарынып, Габдулланың әнисе Мәмдүдә абыстайның нәкъ менә Сасна Пүчинкәсе авылындагы указсыз мулла Мөхәммәтшакирга кияүгә чыгуы турындагы документларны тапты” – дип үзгәртү уңышлырак дип саныйм.

“Худсовет аркылы үткәрә**се** бул**са**, бездә җырлаучы**сы** да, җыры да калма**с** иде”(“Ватаным Татарстан”, 2нче март, 2018нче ел, 18нче бит) җөмләсендә дә бер үк авазның кабатлануы аһәңлелекне боза. “Худсовет аркылы үткәрсәк, бездә җырлаучы да, җыр да калмас иде” дип үзгәртү кулайрак.

Авазлары бер үк булган сүзләр янәшә килсә дә, сөйләмнең аһәңлелеге бозыла. “Арча” **җырын** халык **җыры** дип **җырлап** йөри”(“Ватаным Татарстан”, 23нче март, 2018нче ел, 18нче б.) җөмләсен “Арча”ны халыкныкы дип **җырлап** йөри” дип үзгәртү отышлырак кебек.

“Мәрьям апалары да гомерләренең әнә шулай **агымсудай агуына** күрсенеп куя”(“Ирек мәйданы”, 8нче декабрь 2016нчы ел, 7нче бит) дигән җөмләне “Мәрьям апалары да гомерләренең әнә шулай агымсудай үтүенә күрсенеп куя” дип үзгәртергә кирәк.

“Ватан алдындагы бурычны үтәп кайткач, янгын сүндерү **эшендә эшләп** карадык”(“Ирек мәйданы”, 8нче декабрь 2016нчы ел, 8нче бит) җөмләсен “Ватан алдындагы бурычны үтәп кайткач, янгын сүндерүче булып эшләдек” дисәк, җөмләнең аһәңлелеге саклана.

Сүзләргә татар теленә хас булмаган кушымчалар ялгау да җөмләнең аһәңлелеген киметә.

**“Корытмыйсы** иде шул тамырны”(“Татарстан яшьләре”, 1нче март, 2018нче ел, 7нче бит)җөмләсендә инфинитивның юклык формасы -маска, -мәскә кушымчасы белән ясала, шуңа күрә **корытмаска** дип язарга кирәк.

“Башта Познань шәһәренә барып, аннан электричка белән солдатның **бабае** күмелгән теге кечкенә шәһәрчеккә киттек”(“Татарстан яшьләре”, 1нче март, 2018нче ел, 10нчы бит)җөмләсендә **бабасы** сүзе кулланылырга тиеш.

Эзләнү эше белән шөгыльләнгәннән соң, мин шундый нәтиҗәгә килдем: матбугат язмаларында сөйләм культурасы таләпләренә туры килмәгән очраклар бик күп, төрле характердагы хаталар, төгәлсезлекләр, әдәби тел нормаларын бозулар күзәтелә. Минемчә, тел белән саксыз эш итәргә, аны үзенә ошаганча бозарга беркемнең дә хакы юк. Бу мәсьәләгә игътибар җитеп бетми дип уйлыйм, чөнки фәнни хезмәтләрдә, вакытлы матбугат битләрендә, радио-телевидение тапшыруларында сөйләм культурасына бәйле проблемалар күтәрелми диярлек.

Бүгенге көндә, милли телләрне эзәрлекләү, кимсетү сәясәте алып барылган чорда, без телебезне саклап калу өчен бергәләп көрәшергә тиеш. Телебезне, милләтебезне үзебез хөрмәт иткәндә генә, аны башкалар да хөрмәт итәчәк.

*Кулланылган әдәбият исемлеге:*

1. Кәримуллин Ә.К. Тел – милләтнең сакчысы. - Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1997.

2. Зәкиев М.З., С.М.Ибраһимов. Татар теле. 9 сыйныф: татар телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен уку әсбабы. - Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2015

3. Сафиуллина Ф.С., Ибраһимов Г.Б. Хикмәтле дә, бизәкле дә туган тел: Гомуми урта белем мәктәпләре, гимназияләр һәм лицейларның 5-11 нче сыйныф укучылары өчен тел турында кызыклы материаллар. – Казан: Мәгариф,1998.

4 // Акчарлак, 2018, 12нче гыйнвар,1нче март.

5. // Ватаным Татарстан, 2018, 2нче март, 23нче март.
6. // Ирек мәйданы, 2016, 8нче декабрь; 2017, 19нчы октябрь.
7. // Татарстан яшьләре, 2017, 22нче февраль, 31нче август; 2018, 1нче февраль, 23нче февраль, 1нче март, 7 нче март, 15нче март.
8. // Хезмәт даны, 2018, 16нчы февраль.

## ФАТИХ КӘРИМ ШИГЫРЬЛӘРЕНДӘ ОБРАЗЛЫ ПРЕДМЕТ СУРӘТЛӘҮ ЧАРАЛАРЫ ҺӘМ МЕТАФОРАЛАР

*Замалова Гүзәл Фәрит кызы, 8нче сыйныф укучысы*
*Фәнни җитәкче: Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе Мөслим урта гомуми белем бирү мәктәбенең югары категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы Даутова Гөлчәчәк Минсалих кызы*

Талантлы шагыйрь Фатих Кәрим шигырьләрендәге образлы, предмет сурәтләү чараларын карап үтик. Әдәбияттагы бу чараларны татар телендә семасиология бүлеге өйрәнә. Семасиология бүлегенә сүзнең лексик мәгънәсе һәм аның төрләре, сүздәге мәгънәләрнең үсеш юллары, күчерелмә мәгънәләрнең төрләре карый. Эшебезнең ***төп максаты*** – Ф.Кәрим шигырьләрендәге образлы, предмет сурәтләү чараларын табу һәм аларның төрләрен карау.

Максатыбызга ирешү өчен түбәндәге ***бурычлар*** куелды:

1) әсәрдән образлы, предмет сурәтләү чараларын табу;
2) аларның төзелеш-ясалыш үзенчәлекләрен тикшерү.
3) тропларның киң таралганы - метафора

***Тикшерену методлары***. Эшебездә чагыштырмалы-тарихи, тасвирлама, структур-лингвистик методлар кулланылды.

***Эшнең методологик базасы***. Югарыдагы бурычларны чишү өчен Ф.М.Хатыйпов, Д.Ф.Заһидуллина, Ф.С.Сафиуллина, Ф.Кәрим хезмәтләренә таянып эш ителде.

***Эшнең гамәли әһәмияте***. Образлы предмет сурәтләү чараларының ясалышын,таралыш-кулланылышын,төзелеш үзенчәлекләрен өйрәнүнең тел һәм халык тарихы өчен зур әһәмияте бар, алар ерак үткәннең колоритын, рухын тоярга, борынгы лексика, формаларны үз итүчеләрнең сөйләм үзенчәлеген чагылдырырга ярдәм итәләр.

***Эшнең структурасы***. Хезмәт керештән, өч бүлектән ( I бүлек Ф.Кәрим шигырьләренең көче; II бүлек Ф.Кәрим шигырьләрендәге образлы предмет сурәтләү чаралары; III бүлек Тропларның аеруча киң таралганы-метафора IV бүлек Без ясаган нәтиҗәләр һәм файдаланылган әдәбият исемлегеннән тора.

Фатих Кәрим Ает авылында заманы өчен укымышлы саналган мулла гаиләсендә унберенче – төпчек бала булып дөньяга килә. Үз авылында мәдрәсәдә укый. Абыйсы шагыйрь Ярлы Кәрим, әтисе, апасы да шигърият яраталар, үзләре дә шигырьләр чыгаралар. Сигез яшьтән әтисез калып, балалар йортында тәрбияләнгән.1924 нче елда ул Казанга килә, шунда шигырь язу белән мавыга башлый. Кыска гына иҗат дәверендә Ф.Кәрим күп кенә ялкынлы лирик шигырьләр, поэмалар тудырды. Шагыйрь шулай ук проза һәм драма әсәрләре дә язды. 1929 нче елдан 1937 нче елга кадәрге кыска вакыт эчендә аның ун китабы басылып чыга (икесе-проза, сигезе-шигъри җыентыклар). Ф. Кәримнең поэтик таланты аеруча Бөек Ватан сугышы чорында ачыла. Фронтның авыр шартларына карамастан, Ф. Кәрим сугыш чорында һәр буш минутын иҗат өчен файдалана. 1941-1945 нче еллар арасында ул тугыз поэма, ике повесть, бер драма әсәре һәм йөздән артык шигырь яза.Сан ягыннан гына түгел,

сыйфат һәм идея-эчтәлек ягыннан да шагыйрьнең бу чор әсәрләре иҗатта яңа биеклеккә күтәрелү, камиллеккә ирешү мисалы булып торалар. Аның поэзиясендә сугыш чынбарлыгының катлаулы фәлсәфәсе, туган ил өчен җаннарын кызганмый көрәшкән совет кешеләренең, совет солдатының табигый эчке кичерешләре, патриотик хисләре, сөйгәненә булган олы мәхәббәте, тыныч тормышка сусавы гаҗәеп бер ихласлык һәм шигърилек белән гәүдәләнә.

Бөек Ватан сугышы елларында Ф. Кәрим чәчмә әсәрләр язуга да игътибар бирә:"Шакир Шигаев"(1943) исемле драма,"Разведчик язмалары" (1942) һәм "Язгы төндә"(1944) исемле ике повестен иҗат итә. Бу әсәрләрдә, поэзиясендәге кебек үк, сугыш темасы-батыр совет сугышчыларының җанлы образлары, төрле милләт кешеләреннән оешкан совет армиясенең рухи һәм сугышчан бердәмлеге чагыла.

Әдәби әсәр теленең иң күп өлешен туры мәгънәле сүзләр алып тора. Ләкин язучылар, шагыйрьләр күренешне, аның билгеләрен төгәлрәк белдерү, төсмерләрен нечкәрәк, ачыграк әйтеп бирү максаты белән образлы предмет сурәтләү чараларына мөрәҗәгать итәләр. Аларга синонимнар, антонимнар, омонимнар, эпитетлар, оксюмороннар, чагыштырулар керә.

Алар ерак үткәннең колоритын, рухын тоярга, борынгы лексика, формаларны үз итүчеләрнең сөйләм үзенчәлеген чагылдырырга ярдәм итәләр. Аларны укып, без дә үзебезне шул дәвер кешеләре арасына килеп кергәндәй хис итәбез [Хатыйпов Ф.М., 2000, 120].

Синонимнар дип әйтелешләре, тышкы яңгырашлары белән төрле, ә мәгънәләре бер-берсенә тәңгәл килүче сүзләр атала. Синонимнар язучыларның, шагыйрьләрнең карусыз иҗат дуслары. Мәгънәдәш сүзләр бер үк сүзне кабатлаудан арынырга булышалар. Без Фатих Кәримнең шигырьләрендәге синонимнарның кулланылышын күзәттек.

***Фигыльләр тиңдәшләнеп килгәннәр:***

*Гөрселди* дөнья, янар күк кебек *үкерә* ("Урман тын иде", 1 том, 69б)
*Дулкынланып, шаулап* торган урман
*Сынып беткән, изрәп тапталаган.* ("Бездә яздыр", 1 том77б.)
Яшәдем, яшел урманнар
*Иркәләде, көйләде* (Теләк" 78б.)
Таза, ярсу атлар кирәк (Сагынып көтәм"84б)
*Сүрелде* җил, *тынды* бар дөнья ("Шомырт куагы", 111б.)
Ул *яна, көя* ("Яңгыр астында")
*Ярсып, шаулап* килә дулкыннар ("Казан")

***Исемнәр тиңдәшләнеп килгәннәр:***

*Үч, ачуын, нәфрәт* ялкынын ("Бомба төяп оча самолёт", 92 б.)
Ут булмаган җирдә ай яктырта ("Кереш җыр"1 том, 73 б.)
Ак халатлы егет, ак шәүлә ("Урман тын иде", (1 том, 69б)
*Кара чокыр* булып калды
Зенитка торган урын,
Бу чокыр калганнарыны-
Немец, фин еланнарына
Котылмас *кабер* булыр. ("Шәкүрев турында җыр",103б.)
Иген кыры-байлык диңгезе ("Волхов кырында")
Дар агачы, үлем элмәге ("Халык үче")
Җыр бишегем-Казан кочагы ("Казан")

***Сыйфатлар тиңдәшләнеп килгәннәр:***

Туган илгә көчле, гайрәтле
Кеше...Кеше кирәк чагында ("Кайгың, куанычың" 90б.)
Нурсыз, төссез булган шикелле,
Боек, сүлпән, омтылышсыз була
Хыялсыз көн иткән һәр кеше. ("Минем җырым",97б.)
Таза, ярсу атлар кирәк (Сагынып көтәм"84б)
Кайгы, хәсрәт төяп, мәлгунь немец ("Үлем сиңа")

Без караган синонимнардан иң күбесе фигыльләр тиңдәшләнеп килгән. Шулай ук исем, сыйфат сүз төркеменә караган синонимнар да бар.Туган телнең синонимнарын яхшы белгән кеше үз фикерләрен төгәлрәк һәм матуррак белдерә.Синонимнарны белмәү сөйләмне ярлыландыра, сүз куллануда ялгышларга китерә.

***Фразеологизмнарның кулланылуы:***

*Тешне кысып алган* тирән сулыш (“Бомба төяп оча самолёт”, 92 б.)

*Күзе тонган* фашист козгыны (“Мин гуманист”,98б.), дәвам итте һаман сибүен (“Кысыр чәчәкләр”)

Идел ярына , *башыңны салып (“*Идел”,122б.), нечкәрә күңел (“Аникин”), безгә диңгез тубыктан, таш күңел, йөрәге купкан (“Гөлсем”), эшкә һич күңел бармый (“Тирән күл”), йөрәге таланган(“Яшен яктысы”)

*Антонимнар* капма-каршы мәгънәдәге сүзләр (грекча anti+onomo сүзләреннән ясалган, каршы исем дигәнгә туры килә). Антонимнар катлаулы, каршылыклы халәт-күренешләрне белдерүгә, шул каршылыкны сиздерүгә хезмәт итәләр, кабул итүне үткенәйтәләр. Антонимнарны мәгънәләре ягыннан алты төркемчәгә бүләргә мөмкин.

**1) Күренешләрнең, предметларның, кешеләрнең сыйфатларын тасвирлыйлар:**

Бугазлашкан урман, кырлар (“Бездә яздыр”, 1 том77б.)
Иң *матур* кош тавис диләр,
*Ямьсезмени* безнең карлыгач?! (1 том,89б.)
Үлем көткән *авыру*...яңадан
*Сукса тимер өзәр егет* булып (“Кайгың, куанычың” 90б.)
Мылтык **яңа,** дуслар да яңа,
Окоп *иске,* таныш мин аңа (“Окоп”, 105б.)
Еллар миңа *йомшак* күңел бирде
Еллар мине *усал* да итте. (“Разведкада”, 119б)

**2) Вакыт төшенчәсен белдерәләр:**

Кемгә **кич**, кемгә **иртә (**“Җәйләр җитсә”,17 бит)
Яна көндез, яна кичен (“Җыр”)

**3) Күренешләрнең озынлыгын, күләмен, урнашуын ачыклыйлар:**

Озын сүзнең кыскасы шул (107б)
Төн кыскара бара,
Көн озая (“Илле егет”)

**4) Табигать күренешләрен күрсәтәләр:**

Көн кояшлы, төннәр айлыдыр (“Бездә яздыр”, 1 том77б.)
Йолдыз сүнә, кояш балкый (“Кечкенә хат”)

**5) процессларны каршы куялар:**

*Куанудан шунда еладым* (“Шомырт куагы”,111б.)
Бик *үбәсе килсә* дә, кыз
Түзде ничектер, ләкин юкка *үпмәде.* (“ Юкка үпмәдең”, 113б)
Мәсьәләне сызып кабызуга,
Икенчесе торып сүрелтә.(“Җиденче мичче”)
Мин *янмыйча уттан да үттем*. (“Разведкада”, 119б.)

**6) гомумирәк төшенчәләрне белдерәләр:**

*шаулы* бүлмә тагын *тын* калды(“Җиденче мичче”)

Без антонимнарның мәгънә ягыннан төрләрен карадык. Бар төренә дә мисаллар таптык.Димәк, шагыйрь антонимнарның кулланылышын яхшы белә, аларны тулысынча үзенең шигъри юлларына керткән.Ләкин кайбер төрләргә антонимнар аз күләмдә табылды. Караган шигырьләрдә ***кабатлаулар*** бик күп очрый.Ф.Кәримнең һәр шигырендә диярлек бар.Кабатлаулар шигырьнең хис-тойгы көчен арттыралар.

Бик ямансу миңа, ямансу (“Аның җыры”, 94б.)

Тик онытма, син онытма мине (“Минем җырым”, 96б.)

Йөрәгем яна минем

Яна кичен, яна көндезен (“Исә җил”,102б.)

Көзге төндә яңгыр гына

Сибәли дә сибәли (“Сибәли дә сибәли”,117б.)

Сурәтләү чаралары арасында аеруча *эпитет һәм чагыштырулар* күп кулланыла (epithon кушымта дигән мәгънәне белдерә).

***Эпитет*** предметның, күренешнең сыйфатын, билгесен белдерә.

*Корыч канатлы* яшь лачын (“Шәкүрев турында җыр”, 103б.), *алтын* нурлар (“Тагын да кил,82 б.), *бәхет* гөле булып үсәчәк (“Алга бара идек”, 87б.), *көмеш сулы* тын күлләр, кайгы сөреме (“Кошлар”,123б.), *канатлы* хыялларым (“Хәдичә”, 124б.) , *керсез* күңел ирке (“Диңгез ярында”), *бәхет* күгәрчене (“Кайгырма син”), *кара* язмыш, *кансыз* йөрәк, (“Таш арасында”), *кайнар к*ан , *шатлык* яше (“Кайда минем мылтык”), изү һәм яшәү хисе (“Сапёр”), *ачу* давылы , *коллык* сөреме (“Безнең урамда”), *нәфрәт* ялкыны (“Кемне кызганам”), тезелгәннәр *михнәт* эзләре (“Һөҗүм”, 134б)

***Оксюморон*** эпитетның үзенчәлекле бер төре.Ул каршылыклы, буталчык халәтнең, үзара ярашмаучан күренеш, сыйфатларның катлаулылыгын тәгъбир итүче художество чарасы буларак дөньяга килгән (грекча oxymoron тапкыр-сантый дигән мәгънәгә туры килә [Хатыйпов Ф.М., 2000, 94б.]

Гамьсез ярсу белән килмиләр, җиңел генә ыргып менмиләр (“Дулкын белән сөйләшү”), сагыш ялкынының яктысы (“Ак күбәләк”),

Бәхетем син минем, шатлыгым син

Әрнүле тирән кайгым син (“Ак күгәрчен”)

Зарыгып сыкрый бу күңел (“Алга бара идек”, 86б.)

***Чагыштыру*** - бер күренешне икенче предмет янына куеп, шуңа охшатып, янәшә китереп сурәтләү.

*Таш кебек катып (“Идел”); мин кояшым итеп йөртәм, йөрәк ялкынын (“Кыр казы”); коштай очып килгән бу хаттан, кайнап тамган яшең алмаз бөртегенә охшасын(“Тамсын әйдә”), котырган эт-канлы фрицларны (“Без бергә”), тирес суы төсле кан (“Сапёр”), Әтнекедәй күзе акая (“Халык үче”), кырмыска кебек тынгысыз (“Батыр”), ток шикелле бөтен тәнгә йөгерә, бәрелгән туп кебек,төтен төсле сыерларның күзе,сусаган эт кебек ырлый-ырлый ялкын ялап ала җилкәсен, кара күмер була ярты авыл, күз алмасы суга манчып алган карлыган кебек (“Аникин”),* күзе тонган фашист козгыны (“Мин гуманист”,98б.), арыслandай, кан эчкеч килмешәкләрнең (Сагынып көтәм”84б)”

Язгы тамчылар күк мөлдериләр Күземдәге яшьләр бөртеге (“Алга бара идек”, 86б.)

*Чагыштыруларның күбесе тышкы күренеш белән янәшә килгән. Алар* ***кебек, шикелле,төсле*** *бәйлекләре****, -дәй,-дай,-тай, -тәй*** *кушымчалары,* ***әйтерсең*** *рәвешендәге теркәгеч сүз ярдәмендә, шулай ук янәшә тору юлы белән бирелгәннәр.*

Тропларның аеруча киң таралганы-метафора. Троплар яки ассоциатив сурәтләү чаралары дип күчерелмә мәгънәне төрле әйберләр, күренешләр, предметлар арасындагы бәйләнеш аша барлыкка китерә торган гыйбарәләргә әйтәләр.Алар әдәбиятта образ тудыру, текстның тәэсир көчен арттыру, сурәтләнә торган күренеш-халәтне укучы күз алдына төгәл китереп бастыру өчен хезмәт итәләр [Заһидуллина Д.Ф., 2005, 92]. Тропларның аеруча киң таралганы-***метафора.***Грекча метафора күчерү дигәнне аңлата. Күчерү билгенең охшашлыгына, уртаклыгына нигезләнә.Без тапкан метафораларның мәгънәләрен аңлатырга тырыштык.

*Кара кичнең пәрдәләрен ертып*

Эзли күңел якын иптәшен(“Кайгы”, 118б.)- **юксыну**

Йөрәгемдә ләкин Ленин байрагын

Канат иткән *бөркет җаны* бар. (“Разведкада”,120б.)- **җан үлмәгән, ул көчле**

Көмеш сулы тын күлләр (“Кошлар”,123б.)-**суның чисталыгы, сафлыгы**

*Бугазына элмәк кигезә* (“Кош”)- **асу, үтерү**

Юлбасарның *җаны йөгәнсез* (“Бер төндә”,126б.)-**юлбасар бернәрсәдән дә тайчанмый, эшәкелекнең барысын да эшли**

Зур кайгыга төшсәләр дә

*Караңгыга төшмиләр* (“Син еракта”, 127б.)-**нинди генә авырлыклар булса да,пычраклык эшләргә намуслары кушмау**

Һәм түбәннән *тормыш яктылыгын*

Өмит итеп өскә менгәндә (“Һөҗүм”)- **җиңү якынлашу**

Таптап үтәм *үлем чокырларын* (“Үлем синә”)- **һәркайда син үләргә мөмкин**

*Канатларын кагып сызгыра җил* (“Совет солдаты”)-**нииндидер хәбәр көтү**

Ут әчесе тоеп кайгы эчкән – **бик күпне кичергән**

Халык *күңеле тирән яралы* (“Халык үче”)-**бик борчулы, кайгылы**

*Каргалган ил кара сөрем булган-* **янган, хәерчеләнгән**

*Үзе утка төшкән ут иле (“Кемне кызганам”)-* **сугышның бетмәс-төкәнмәс кайгы алып килүе**

*Җилфердәп тораларҗилдә*

*Өмет чәчәгем булып.(“Бизәкле ал яулыгың”)-***кайту өмете**

Фатих Кәрим шигырьләрендә метафоралар бик күп кулланыла. Шигырьнең көче метафоралар ярдәмендә ачыла. Нәтиҗәләр:

1.Синонимнардан иң күбесе фигыльләр тиңдәшләнеп килгәннәр. Шулай ук исем, сыйфат сүз төркеменә караган синонимнар да бар.

*Дулкынланып, шаулап* торган урман

*Сынып беткән, изрәп тапталаган.* (“Бездә яздыр”)

Ак халатлы егет, ак шәүлә

2.Антонимнарны мәгънәләре ягыннан алты төркемчәгә бүләргә мөмкин. Һәр төркемчәгә дә мисаллар таптык:1)к**үренешләрнең, предметларның, кешеләрнең сыйфатларын тасвирлыйлар:**

Иң *матур* кош тавис диләр,

*Ямьсезмени* безнең карлыгач?! (1 том,89б.)

**2)вакыт төшенчәсен белдерәләр:** Яна көндез, яна кичен (“Җыр”)

**3)күренешләрнең озынлыгын, күләмен, урнашуын ачыклыйлар:**

Озын сүзнең кыскасы шул (107б)

**4)табигать күренешләрен күрсәтәләр:җир-су;**

Көн кояшлы, төннәр айлыдыр (“Бездә яздыр”, 1 том77б.)

**5)процессларны каршы куялар:**

Мин диңгезгә *батып тере калдым*

Мин *янмыйча уттан да үттем.* (“Разведкада”, 119б.)

**6)гомумирәк төшенчәләрне белдерәләр:**

*шаулы* бүлмә тагын *тын* калды(“Җиденче мичче”)

3. Чагыштыруларның күбесе тышкы күренеш белән янәшә килгән. Алар **кебек, шикелле, төсле** бәйлекләре**, -дәй,-дай,-тай, -тәй** кушымчалары, **әйтерсең** рәвешендәге теркәгеч сүз ярдәмендә, шулай ук янәшә тору юлы белән бирелгәннәр.

4.Өйрәнгән шигырьләрдә эпитетлар: *корыч канатлы* яшь лачын (“Шәкүрев турында җыр”, 103б.), *алтын* нурлар (“Тагын да кил,82 б.); һәм метафоралар бик күп кулланылган:

Юлбасарның *җаны йөгәнсез* (“Бер төндә”,126б.)-**эшәкелекне, пычраклыкны эшләргә тайчанмый**

Халык *күңеле тирән яралы* (“Халык үче”)-**бик борчулы, кайгылы**

5. Шигырьләрдә халык мәкальләре дә урын алган. Без шушы өйрәнгән шигырьләр арасыннан икене таптык.

Теләк булса, тауны тишәсең (“Бер төндә”)

Куркактан үлем көлә (“Хәнҗәр”)

Ф.Кәрим шигырьләренең халыкчанлыгы, аһәңе менә шушы сурәтләү чараларында инде.Шигырьләрнең яңгырашы да сурәтләү чараларына бик нык бәйле.

*Файдаланган әдәбият исемлеге:*

1.Заһидуллина Д.Ф./Әдәбият белемеТерминнар һәм төшенчәләр сүзлеге/-Казан: Мәгариф, 2007.

2.Кәримов Ф./Поэмалар, балладалар һәм драма 1929-1945, II том/-Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1980.

3.Сафиуллина Ф.С./Татарча-русча фразеологик сүзлек/-Казан: “Мәгариф” нәшрияты, 2001. 4. Сафиуллина Ф.С., Зәкиев М.З.”Хәзерге татар әдәби теле”/-Казан: Мәгариф, 2002.

5. Хатипов Ф.М. Әдәбият теориясе/-Казан: Мәгариф, 2000. 6.Яхин А.Г. Әдәбият/ – Казан: Мәгариф, 2001.

## ЯКТАШ ШАГЫЙРЬ – ӘХМӘТ ЮНЫС

*Камалова Йолдыз Илдар кызы, 5 нче сыйныф укучысы*
*Фәнни җитәкче: Гайнетдинова Нәфисә Хабибулла кызы, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы муниципаль бюджетгомумбелем бирү учреждениесе “Кукмара ш.т.п. А.М.Булатов исемендәге күппрофильле лицей”ның татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

Лицеебыз диварын бизәүче “Горурлыгың синең, Кукмара” дигән стендта якташ язучылар һәм шагыйрьләр турында мәгълүматлар урнаштырылган. Кемнәр алар горурланырдай кешеләр? Үткән саен тукталып, якташларым тормышы һәм иҗаты белән кызыксынам. Араларында, инде тууына 100 ел тулган, язучы Әхмәт Юныс та бар. Аның турында күбрәк белү теләге белән татар теле һәм әдәбияты укытучысына мөрәҗәгать иттем. Ул миңа Әхмәт Юныс турында мәгълүматлар тупларга, эзләнергә киңәш бирде.

Эшемнең максаты: Әхмәт Юнысның тормыш юлы һәм иҗаты белән танышу.

Эшемнең бурычлары: шагыйрьнең китапларын барлау; шигырьләренең тематикасын билгеләү; исемен мәңгеләштерү буенча нинди эшләр алып барылуын ачыклау.

Эзләнү эшенең объекты: Әхмәт Юныс.

Эшемнең әһәмияте: туган як әдипләренең тормышы, эшчәнлеге белән танышмыйча, дөньякүләм танылган бөек шәхесләрнең иҗатын югары дәрәҗәдә күзаллау мөмкин түгел дип уйлыйм. Галим Ризаэддин Фәхретдин “Әдип вә галимнәре булмаган халык бәхетсез, мәшһүр кешеләрен оныткан халык көчсез, әдәбияты булмаган милләт рухсыз”, - дип әйтеп калдырган. Без, яшь буын, туган төбәгебездән чыккан күренекле кешеләр, язучылар турында белергә тиеш.

Беренче эш итеп, район китапханәсенә юл тоттым һәм Әхмәт Юныс турында район һәм республика матбугатында чыккан мәкаләләр белән таныштым. Интернет челтәрендә булган материалларны укыдым, Зөмәрә Нихатовна җитәкчелегендә чыгарылган “Якташ язучылар” дәреслек хрестоматиясеннән эшем өчен файдалы булган мәгълүматлар таптым. Укытучым белән шагыйрь туып үскән Әсән-Елга авылында булдык. Авыл китапханәсендә сакланган материалларны карадык. Әхмәт Юныс яшәгән йортның безнең көннәргә кадәр сакланмаганын ачыкладык.

**Әхмәт Юнысның тормыш юлы**

Гади генә бер авылда, гади булса да үзенең хезмәт сөючән тырыш халкы белән тирә-юньдә дан тоткан Кукмара районының Әсән-Елга авылында, 1916 елның 15 нче октяберендә урта хәлле крестьян Юныс ага гаиләсендә Әхмәт исемле малай дөньяга килә. Ул вакытта башка яшьтәшләреннән берни белән дә аерылып тормаган малайның киләчәген, язучы булып китәчәген кем белгән дә, кем уйлаган соң? 1928 елда, туган авылы Әсән-Елгада башлангыч мәктәпне тәмамлаганнан соң, Әхмәтне Мәчкәрә мәктәбенә илтеп бирәләр. Белергә омтылу,

тирә-юньгә кызыксынулы караш ташлап яшәүче малайга мәктәптә тудырылган уңайлы мохит тумыштан килгән сәләтен үстерү өчен бик уңайлы булып тоела.

Унбиш яшьлек Әхмәт Юныс 1931 елда җидееллык мәктәпне тәмамлаганнан соң, Каенсар авылына эшкә китә. Башта мәктәптә укытучы, ә аннан соң мәктәп директоры хезмәтен башкара. Бу хезмәте аның 1935 елга кадәр дәвам итә. Каенсардан Чиләбе өлкәсендәге Копейск шәһәренә юл тота һәм анда да укытучы булып эшли.

Яшь егет Әхмәт Юнысны татар шахтерлары күпләп яшәгән Донбасс якларына җибәрәләр. 1936-1937 елларда “Үзәк” шахтасында аңа йөзләрчә татар-башкорт шахтерлары белән мәдәният эшен оештыру, сәяси хәлләрне аңлатып бару эшләрен тапшыралар. Һәвәскәрләр белән концерт-спектакльләр куюны, агитация эшләре уздыруны Әхмәт зур җаваплылык белән башкара. Сценарийлар төзи, шигырьләр яза. Донбасс җирлегендә иҗат ителгән шигырьләре “Гүзәл яшьлек” исемле җыентыгында басылып чыга.

1939 елда фин сугышы башлангач, үзе теләп армия сафына баса һәм сугыш хәрәкәтләрендә катнаша. 1940 елда демобилизацияләнеп кайткач, Ә.Юныс «Яшь сталинчы» газетасында эшли. Бу елларда яшь шагыйрьнең шигырьләре һәм поэмалары тупланган «Тантана» (1939) һәм «Әсән-елга» (1941) исемле ике җыентыгы басылып чыга.

Сугышның беренче елларында Ә. Юныс Апас районының Чурибураш МТСы политбүлегендә эшли. 1942 елда Бөек Ватан сугышына китә. 1942-1943 елларда ул «Ватан намусы өчен» исемле фронт газетасында хезмәт итә, КПСС сафларына кабул ителә. Фронтта иҗат итүдән туктамый. Сугышчылар белән очрашып, аларга үзенең шигырьләрен укый.

Кузгал, улым, тиз бул, тиз  
Әнә –  
Йортыбызга кергән талаучы...  
Балакаем, безне яклачы! –  
Газиз илгә дошман кизәнә.

Ул аларга унбишләп шигырен яттан сөйли. Ялкынлы шигырьләре сугышчыларга рух бирә, көч өсти.

1945-1949 елларда шагыйрь Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетында укый. Аның белән бергә укыган фронтовик шагыйрь Мәхмүт Хөсәен болай дип искә ала: “Нинди генә фәннән булмасын, ул һәрвакыт әйбәтләп әзерләнеп килә. Дәресләрдә үзе кул күтәреп сөйләми, сорасалар, җиренә җиткереп сөйләп бирә. Кичәләр, төрле чаралар оештырырга аңа кушалар, ул аларны мавыгып бшкара.” Укуын уңышлы тәмамлагач, “Яшь сталинчы” газетасы редакциясендә эшли, 1951-1954 елларда “Пионер” журналының җаваплы секретаре, 1957-1958 елларда Татарстан китап нәшриятының яшьләр-балалар әдәбияты редакциясе мөдире булып тора.

Ә.Юныс – 1939 елдан СССР (Татарстан) Язучылар берлеге әгъзасы. Каләмдәшләре аның турында җылы сүзләр әйтеп калдырган. Әхмәт Юнысның “Туган җирем, сиңа җырым” китабына кереш сүзне шагыйрь Сибгат Хәким язган. “ ...Кече яшьтән үк кырларда эшләп үскән егет. Җил-җил килеп йөрүе белән әле дә кырдан игеннәр карап кайтучыны хәтерләтә. Фин сугышында, Бөек Ватан сугышында катнашкан солдат та. Кыскасы, халык кичергәннәрне кичереп яшәгән шагыйрь. Аның поэзиясендә үз биографиясе ярылып ята... Үзенчәлекле шагыйрь буларак, Әхмәт Юныс үзен хезмәтне җырлауда, хезмәт кешесенең уй-тойгыларын гәүдәләндерүдә тапты”, - дип яза шагыйрь. Кеше буларак туры сүзле , кыю шәхес булуын да искәртеп үтә.

Әхмәт Юныс Хәсән Туфан белән бик якын дус була. Хәсән Туфанны, репрессия корбаны буларак, Свияжскига төрмәгә ябалар. Ә.Юныс тормыш иптәше Гөлсем апа белән аның янына хәл белергә килә. Ә.Юнысның шул гамәле батырлыкка тиң, ул үз язмышын куркыныч астына куеп, Хәсән Туфанның гаепсез икәнлеге турында Мәскәүгә хат тапшырырга бара. Өч көн чират торганнан соң, ул СССР Верховный Советы Президиумы председателе Шверник янына керә ала. Шверник Х.Туфанның ничәнче статья белән утырганын сорый һәм Әхмәт Юнысның үтенечен кире кага. Хәсән Туфанга ярдәм итә алмаса да, Ә.Юнысның бу адымы- батырлык. “Шушы кыюлыгы һәм кешечә мөнәсәбәтләргә

тугрылыгы өчен генә дә Әхмәт Юнысның исеме әдәбиятыбыз тарихына алтын хәрефләр белән язылырлык", - дип яза Фоат абый Галимуллин "Хезмәт даны" газетасында чыккан мәкаләсендә.

"Әхмәт Юныс кая гына барса да, нинди генә озын юллар үтсә дә халык арасында булды, халыкның шатлыгын да, кайгысын да уртаклашты. Шагыйрь үзенең әсәрләрендә халыкның уй-хисләрен сурәтләде, ил һәм халык белән бераяктан атлап барырга тырышты", - дип яза Самат Шакир.

Әдип, озакка сузылган каты авырудан соң, 1976 елның июлендә Казанда вафат була.

2015 елның августында Әхмәт Юнысның кызы Сафия, оныгы Алсу гаиләләре белән Әсән-Елга авылында кунакта булып киткәннәр. Алар әбиләренең каберенә барганнар, китапханәдә шагыйрьгә багышланган күргәзмә белән танышканнар. 2016 елда Әсән-Елга авылында шагыйрьнең 100 еллык юбилееен зурлап үткәрәләр. Чарада Казан һәм Чаллы шәһәрләреннән килгән танылган язучылар, шагыйрьләр, галимнәр, журналистлар, Кукмара районы хакимияте вәкилләре, шагыйрьнең туганнары, якташлары катнаша.

Якташ шагыйрь Әхмәт Юныс минем күз алдыма туган җирен, халкын яратучы, үз эшенә җаваплы караучы, батыр, сәләтле, максатчан, шул ук вакытта тыйнак шәхес буларак килә. Беренче планга ул үз мәнфәгатьләрен куймый, ә дусларына, якын кешеләренә ярдәм кулы сузуны бурычы дип саный.

Ә.Юныс – дистәгә якын шигырь китаплары авторы.Әдәбиятка ул 30 нчы еллар ахырында килә.1937 елда Чиләбе өлкәсеннән Казанга кайта һәм монда аның "Гүзәл яшьлек" исемле беренче китабы чыга. Китапның редакторы Нур Баян яшь шагыйрьдә өмет барлыгын күрә, киләчәктә тагын да тырышып иҗат итәргә куша. Үзенең әсәрләрендә ул үзе яшәгән чорның героикасын, совет кешеләренең хезмәттәге һәм фронттагы батырлыгын, милләтләр арасындагы дуслык хисләрен чагылдырырга омтыла. Шагыйрь күңеленә үзенең авылында узган балачагы, әнисенең һәм авылдагы кызларның урак урган кояшлы көннәре мәңгелеккә кереп кала. Ул гөрләп эшләп йөргән комбайннарга бераз куркып та, сокланып та карый кебек, ә күз алдында урак уручы авылдаш апалары. Игенче һөнәренә дан җырлый, аның геройлары югары уңыш алыр өчен көрәшә:

...Белә бит ул җирдә шушыннан да
Игелеклерәк һөнәр юклыкны.("Икенче уңыш")
Олы абыең тырыш!
Ул бригадир колхозда.
Үстергәнгә мул уңыш,
Мактый аны барсы да. ("Мин менә кем булырмын!")

Шагыйрь кечкенәдән эшне яратып үсү, үзеңнең күңелеңә хуш килердәй һөнәрне сайлау, кешеләргә яхшылык эшләү турында яза.

...Бәхет юлдаш – кулы тырышка,
Тырышларга юлдаш хыялны
Ашырсана, энем, тормышка!("Йөгер инде аның артыннан")

1939 елда, укытучы булып эшләвеннән чыгып һәм үзенең дә беренче укытучыларын искә алып, "Укытучы тойгысы" дигән шигырен яза. Бу шигырендә Әхмәт Юныс безгә: "Балалар-безнең киләчәгебез", - дип әйтергә тели. Көз көне булса да, укучы мәктәпкә зур теләк белән бара. Үз сыйныфына "хуҗа" шикелле керә, укытучы каршына утыра. Бала остазын бик зур игътибар белән тыңлый. Укытучы укучыны күзләреннән аңлый, йөрәгеннән чыккан мәхәббәте белән үз гыйлемен балага җиткерә.

Ә.Юныс әтисенә гаять дәрәҗәдә рәхмәтле була һәм үзенең "Шулай кайтып киләм" дигән шигырен яза. Бу шигырендә автор авыл кешесенең кырда эшләп арганнан соң, өйгә кайтканда уйланып, хыялланып кайтуын, гади хезмәт кешеләренең якты киләчәккә омтылуларын калку итеп сурәтли. Агай үзенең уйларында киләчәк тормышны гүзәл итеп күз алдына китерә. 1940 елда хәрби хезмәттән кайткач, Әхмәт Юныс яңадан "Яшь сталинчы" газетасындагы эшен дәвам иттерә. Бу елларда шагыйрнең шигырьләре һәм поэмалары тупланган "Әсән-Елга" исемле җыентыгы басылып чыга. Якташым үзенең туган

авылын, аның кешеләрен хөрмәт иткән һәм яраткан. Бу хис аның шигырьләрендә, бигрәк тә "Әсән-Елга"поэмасында ачык сизелә. Әхмәт абый әнисе янына авылга еш кайта торган була. Ул авыл башына кайтып кергәндә инде караңгы төшкән, авылның икенче башыннан гармун тавышы, егетләрнең моңлы итеп җырлаулары ишетелә торган булган. Алар шагыйрь күңеленә яңа дәрт, яңа көч өстәгәннәр.

Әсән-Елга, ямьле Әсән-Елга!
Мин кайтырмын сиңа тагын да,
Алмагачлар үсеп шушы юлга,
Алмалары пешкән чагында...("Әсән-Елга")

"Ватан-анабыз" шигырендә киләчәккә өмет, Ватаныңа хезмәт итү турында язылган:

Ватан дибез. Ватан сүзендә
Чагыла безнең иң саф, зур хисләр.
Тизрәк үсеп, Аңа безнең дә
Күрсәтәсе килә зур эшләр!

Бөек Ватан сугышы елларында Ә.Юныс бик актив яза. Фронт һәм тыл турында язылган шигырьләре һәм очерклары газета-журналларда еш басыла, радиолардан яңгырый. Ялкынлы әсәрләре сугышчыларга рух бирә, шул шигырьләрне укып, алар алга юл яралар, канлы атакага күтәреләләр.

Балачак, балалар турында язылган шигырьләре дә иҗатының бер өлеше булып тора. Шагыйрь үзе дә сабыйлар белән бергә шатлана, уйный, көлә, матур хыяллар белән яши. Аның "Лагерь иртәсе", "Җыр йөри учак янында", "Яңа ел иртәсе" шигырьләрендә бәхетле киләчәк, матур тормыш чагылыш тапкан.

Көймәләр йөзә Иделдә...
Монда безгә бары да бар.
Без иректе туган илдә
Иң бәхетле балалар! ("Лагерь иртәсе")

"Без бәхетле балалар" дип берничә шигырендә кабатлый шагыйрь. "Яңа ел иртәсе" әсәрендә бу фикер тагын бер кат раслана.

- Илебез матур,
  Шатлыгыбыз мул!
  Тагын да артыр
  Бәхетебез быел!

"Илдарның өне, төше һәм тагын бер көне", "География дәресендә", "Аннары... соңыннан..." шигырьләрендә мәктәп укучылары турында сүз бара. Уңай геройлар белән бергә тискәре образларны да очратабыз. "Аннары... соңыннан" шигыренең герое Илгиз дәресләрен хәзерләмәүче, дәрестә игътибарсыз утыручы малай буларак сурәтләнә. Аннары дия-дия бер эшен дә вакытында эшләми һәм кыен хәлдә кала:

Җавап биргән чагында
Илгиз оятка кала –
Икеле билге ала.

Яхшы укырга, бишле билгеләре алырга омтылган Сәйдә турында "Сәйдәнең абыйсы" дигән шигырендә укыйбыз. Шагыйрь абый белән сеңелнең дустанә мөнәсәбәтен дә күрсәтә.

Берсе уйный, берсе бии,
Җырлыйлар икәү бергә,
Күр, Сәйдә белән Ярулла
Нинди дус икән менә!

1955 нче елда "Кырларга сәяхәт", 1963 нче елда "Булдырасың болай син генә", 1965 – "Канатлана күңел", 1966 – "Туган җирем, сиңа җырым", 1974 –"Бәхет", 1976-"Үземнең язым" дигән китаплары дөнья күрә. Ул шулай ук үзен тәрҗемә итүдә дә сынап карый. К.Чуковскийның "Юындыр", С.Маршакның "А"дан "Я"га кадәр күңелле сәяхәт", А.Бартоның "Кече энем" әсәрләрен татарчага тәрҗемә итә.

Гомумән алганда, Әхмәт Юныс иҗатында хезмәт, туган җир, сугыш темалары өстенлек итә. Балалар өчен язылган шигырьләрендә бәхетле балачак тасвирлана, балалар илнең киләчәге дигән фикер ассызыклана.

Без, Кукмара төбәгендә яшәүчеләр, Әхмәт Юныс кебек якташ шагыйрьләребез белән горурланырга тиеш, алар салган сукмактан атлаган туган җанлы кеше беркайчан да туры юлдан тайпылмас. Эш барышында мин якташым турында күп мәгълүматлар белдем, иҗаты белән таныштым. Әсән-Елга авылында һәм Кукмарада аның исемен йөртүче урамнар барлыгын ачыкладым. Лицеебызның өч укучысы Кукмарада шагыйрь исемен йөртүче урамда яши. Алар Әхмәт Юныснең якташ шагыйрь икәнлеген беләләр. 5-8 нче сыйныф укучылары арасында якташларыбызны beləсезме дигән сораштыру үткәрдем. Сораштыруда катнашкан 50 укучының 28е Әхмәт Юныснең кем икәнлеген белүләрен җиткерделәр. Шагыйрьнең исемен мәңгеләштерүгә Әсән-Елга авылы китапханәчесе Әлфинә апа зур хезмәт куйганлыгын аңладым. Ул шагыйрьнең дипломнарын, каләмдәшләре белән төшкән фотоларын туплаган. Әхмәт Юныснең туган көнен Әсән-Елга авылында ел саен билгеләп үтүләре турында белдем.

Һәр төбәкне дөньяга танытучылар ул – аның күренекле шәхесләре. Безнең Кукмара төбәге исемнәре билгеле, танылган язучылары, шагыйрьләре белән дан тота. Шуларның берсе булган Әхмәт Юныс турында белик, аның исемен, иҗатын буыннан-буынга тапшырыйк.. Чыгышымны Пычак авылы кызы Ландыш Габдрахманова шигыреннән өзек белән тәмамлыйм:

**Синең горурлыгың, Кукмара!**

Безнең якның данын күтәрерлек
Даһи затлар яши дөньяда.
Әхмәт Юныс, Фоат ага да бит –
Горурлыгың синең, Кукмара!
...Рәхмәт сиңа, изге туган ягым,
Тудыргансың бөек шәхесләр.
Халкым киләчәге аның үткәнендә,
Алар хезмәтеннән өлеш бар.

*Кулланылган әдәбият һәм чыганаклар:*

1.Галимуллин Ф. Үз чорының лаеклы шагыйре// Мәдәни җомга.- 2016. – 3 ноябрь.
2.Галимуллин Ф. Кукмараның зур шагыйре//Хезмәт даны.-2016. – 14 октябрь
3.Хәйри Х. Тормыш поэзиясе // Х.Хәйри. Әдәбият һәм тормыш. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1953.
4.Шакир С. Туган җиргә гашыйк // Соц. Татарстан. – 1976. – 15 окт.
5. Юныс Ә. Бәхет.Казан: Татар. кит. нәшр., 1974.
6. Якташ язучылар. Дәреслек хрестоматия. 2003.

## ЛЕВ ТОЛСТОЙ МИРАСЫНЫҢ ТАТАР ӘДӘБИЯТЫНДАГЫ УРЫНЫ

*Кәримова Ләлә Рамил кызы, 9нчы сыйныф укучысы*
*Фәнни җитәкче: Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы МББУ “Түнтәр гомуми урта белем мәктәбе”нең*
*югары категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы*
*Нәкыйпова Лилия Мөнир кызы*

Һәрбер милли әдәбият башка халыкларның сәнгате һәм әдәбияты белән тыгыз мөнәсәбәттә яши. Үзара бер-береңнән өйрәнү, тәҗрибә алмашу, иң яхшы сыйфатларны үзеңдә булдырырга омтылу – әдәбитя үсеше өчен генә түгел, рухи тормыш үсеше өчен дә

мөһим шарт. Милли әдәбиятларның үсеш чорына (татар әдәбиятында 19 йөзнең ахыры – 20 йөзнең башы) тәрҗемәнең активлашуы хас була. Безнең татар әдәбияты башка халык телләреннән тәрҗемә ителгән җәүһәрләр белән баетылган.

**Эшемнең актуальлегенә килсәк,** беренчедән, рус классигы, мәгърифәтче, публицист, фәлсәфәче Лев Николаевич Толстойның (1828—1910) тууына быел 190 ел. Аның тормышының Казаныбыз белән бәйлелеген исәпкә алсак, темабызның актуаль булуы тагын да ассызыкланыр. Икенчедән, әдәби тәрҗемәнең стилистик үзенчәлекләренең сакланышын өйрәнү киң өйрәнелгән өлкә түгел. Өченчедән, әдәби тәрҗемәләр буенча күзәтү уздырып, кызыклы нәтиҗәләр ясау минем өчен кирәкле шәйдер, чөнки татар әдәбияты, тарих, рус әдәбияты минем кызыксындыручы өлкәләр.

**Эшемнең максаты:** Лев Толстойның татар теленә тәрҗемә ителгән бай әдәби мирасы белән танышу; тәрҗемә әсәләренең максаты һәм әдәби тәрҗемәчегә куела торган таләпләр белән танышу.

Эшне тормышка ашыруда төп чыганаклар – Лев Тостойның тәрҗемә әсәрләре, интернет материаллары, әдәби уку әсбаплары. Эзләнү эшемнең **төп методлары**: уку, күзәтү, интервью, анализ һәм синтез.

Эшемне тормышка ашыру өчен т**өп максат итеп** – тәрҗемә өлкәсенә караган хезмәтләр белән танышу; Лев Николаевич Толстойның татар теленә тәрҗемә ителгән әсәрләре һәм тәрҗемәче авторлар белән танышуны куйдым.

Шушы максатны тормышка ашыру өчен, түбәндәге **бурыч** куелды:

- Лев Николаевич Толстойның татар теленә тәрҗемә ителгән әсәрләре һәм әдәби тәрҗемәгә караган хезмәтләр белән киңрәк танышу.

Тикшерү предметы – Әдәби тәрҗемә өлкәсенә караган хезмәтләр, Л.Н.Толстойның тәрҗемә әсәрләре текстлары. Бүгенге көндә мин күп материал туплadым һәм **максатыма ирешү өчен**, түбәндәге хезмәтләр белән таныштым: А.Г. Әхмәдуллинның “Әдәбият белеме сүзлеге” (1990); Г.М. Сафиуллина, Ф.Ф. Хәсәнова, Ә.Г. Мөхәммәтҗанова ларның Әдәби уку (2014) уку әсбабы; Л.Н. Толстойның “Егетчак” Повесте ( 1957); А.И.Шифманның “ Страницы жизни Л.Тостого” (1983); Р.А.Юсуповның Тәрҗемәнең теоретик һәм практик мәсьәләләре (2011) һ.б. Эшнең төзелешенә килгәндә, ул Кереш, Төп өлеш, Йомгаклаудан һәм файдаланылган әдәбият исемлегеннән тора. Керештә әлеге эшнең актуальлеген һәм максатын билгеләдек, төп бурычлар ачыкланды, тикшерү объекты күрсәтелде, безнең темага караган хезмәтләр барланды.Төп өлештә тәрҗемә өлкәсенә караган хезмәтләр барланды, Л.Н.Толстойның татар теленә тәрҗемә ителгән әсәрләре, тәрҗемәчеләр ачыкланды. Йомгакта төп нәтиҗәләрне яздым, соңыннан әдәбият исемлеге китерелде.

Тәрҗемә төрләре арасында иң катлаулы һәм авыр төрләрнең берсе булган әдәби тәрҗемә ул – бер телдә язылган әсәрне, аның стилистик үзенчәлекләрен мөмкин кадәр саклап калырга тырышып, икенче телгә күчерү. Оригиналь иҗаттан аермалы буларак, әдәби тәрҗемәгә оригиналга бәйлелек хас. Әдәби тәрҗемәнең максаты – теге яки бу милләтнең рухи казанышы, хәзинәсе булган матур әдәбият әсәрен башка халыкларга җиткерү, әдәби багланышларны ныгыту. Бурычы – белем, мәгълүмат бирү, матурлык хисе тәрбияләү. Теләсә нинди матур әдәбият әсәре тәрҗемә ителә алмый.

Тәрҗемә эшен ике телне дә яхшы белгән тәрҗемәче башкара. Тәрҗемәчедән, иң беренче чиратта, интеллект, зәвык сорала. Тәрҗемәченең әсәрнең асылын, эчтәлеген, идеясен аңлавы, тәрҗемә берәмлекләренә (сүз, сүзтезмә, җөмлә) структур-семантик эквивалентлар таба белүе әһәмиятле.

Әдәби тәрҗемәчегә куелган **таләпләр:**

1) тәрҗемәдә оригиналның мәгънәсе, эчтәлеге тулы бирелү;

2) төп нөсхәнең форма үзенчәлекләре, автор стиле, сәнгать-милли үзенчәлеге тәрҗемәдә мөмкин булганча тулы гәүдәләнү;

3) сайлап алу, эзләү, иҗат ирege. Шулай да тәрҗемәче иҗат ирегеннән дөрес файдалана белергә тиеш, чама хисен аңларга, сак килергә тиеш. Тәрҗемәче, үзе теләгәнчә,

текстны үзгәртеп, үзирекле тәрҗемә белән мавыгып, авторга хыянәт итә алмый. Дөрес, тәрҗемә тарихында авторны төзәтү, әсәрне шомарту күренешләре дә күзәтелә.[15]

Рус язучыларын өйрәнү, әсәрләрен тәрҗемә итү, ияреп язу XIX гасырда ук башланган булса да, 1905 елдан соң аеруча колач ала. Татар әдипләре А.С.Пушкин, М.Ю.Лермонтов, Н.В.Гоголь, Л.Н.Толстой, А.И.Куприн, А.П.Чехов, И.С.Тургенев һ.б. әсәрләренә мөрәҗәгать итәләр. Шул рәвешле, башка халыкларның әдәби үрнәкләре белән танышу татар язучыларына иҗтимагый-сәяси үзгәрешләрнең асылына төшенергә булыша, үз халкының тарихын аңлау, үсү җирлекләрен билгеләргә мөмкинлек бирә.

Татар теленә киң тәрҗемә ителүе ягыннан бу чорда беренче урынга рус әдәбияты чыга. Рус әдәбиятыннан Л.Н. Толстой, И.А. Крылов, А.П. Чехов, И.С. Тургенев, А.И. Куприн, Н.В. Гоголь, М.Ю. Лермонтов, А.С. Пушкин һ.б. күп кенә рус язучыларының әсәрләре басылып килә. Әсәрләре татар теленә күп тәрҗемә ителгән язучылар арасында иң беренче урында А.М.Горький тора.

А.М.Горький, А.С.Пушкиннан кала татар телендә Л.Н.Толстой, А.П.Чехов, И.С.Тургенев , М.Ю.Лермонтов. һ.б. әсәрләре күп мәртәбәләр басылып чыкканнар.

Татар теленә иң күп тәрҗемә ителгән әдәбият –классик рус әдәбияты.

Рус теленнән татар теленә матур әдәбият әсәрләрен беренчеләрдән булып Мартиньян Иванов тәрҗемә иткән. Каюм Насыйри – Л.Н.Толстой әкиятләрен, И.А.Крылов мәсәлләрен, Таиб Яхин – А.С.Пушкин, А.Н.Афанасьев әкиятләрен; Мөхәммәтсәлим Өметбаев А.С.Пушкинның «Бакчасарай фонтаны»н тәрҗемә итә. Ул чордагы актив тәрҗемәчеләр: Гаяз Исхакый, Габдулла Тукай, Сәгыйть Рәмиев, Галиәскәр Камал, Солтан Рахманкулов, Идрис Багданов һ.б.

Тәрҗемәләр, кагыйдә буларак, ирекле рәвештә эшләнә. Татар теленә тәрҗемә тарихы бөек шагыйрь Габдулла Тукай исеме белән бәйле. Тукай мәдрәсәдә укыган елларда ук Крыловның 75 мәсәлен тәрҗемә иткән. Соңрак Г.Тукай Пушкин, Лермонтов, Жуковский, Фет, Тютчев, Майков, Ушинский, Кольцов һәм башка язучыларның әсәрләрен татарчага тәрҗемә итә. Тәрҗемәнең дәүләт күләмендә зур эш булып китүе Октябрь революциясеннән соңгы елларга туры килә.[16]

Татар теленә чыккан әсәрләренең күплеге буенча беренче урында А.М. Горький тора. 1918-1962 елларда аның әсәрләре татар телендә 64 тапкыр басылып чыккан. А.С.Пушкин – 53 тапкыр, Л.Н.Толстой – 34 тапкыр, А.П.Чехов – 21 тапкыр, И.С.Тургенев – 15, М.Ю.Лермонтов – 14 тапкыр бастырыла.

Бер үк әсәр берничә тәрҗемәче тарафыннан эшләнеп, төрле вариантларда басылу фактлары да бар. М.Горькийның “Ана” романы башта Фәтхи Бурнаш тәрҗемәсендә, аннары Мәхмүд Максуд тәрҗемәсендә чыккан. Грибоедовның “Акыллылык бәласе”н башта Нәкый Исәнбәт, Соңыннан Габдулла Шамуков тәрҗемә иткән. Билгеле бу тәрҗемәләрнең һәркайсында үзенчәлекле яклар бар.

Совет чоры татар әдәби тәрҗемә өлкәсендә чын мәгънәсендә «алтын чор» булып таныла, бу дәвердә татар әдәбиятын күп кенә тәрҗемәләр белән баеткан тәрҗемә мәктәбе барлыкка килә: Кәшфи Басыйров, Сәрвәр Әдһәмова, Ибраһим Гази, Абзал Шамов, Кыям Миңлебаев, Рәис Даутов, Вакыйф Зыятдинов, Фәния Гайнанова, Яхья Халитов, Таһир Нурмөхәммәтов, Саимә Ибраһимова, Лирон Хәмидуллин (прозада); Әхмәт Фәйзи, Фәтхи Бурнаш, Әхмәт Исхак, Нури Арсланов, Салих Баттал, Шәйхи Маннур, Әхмәт Ерикәй, Әнвәр Давыдов, Мостафа Ногман, Зәки Нури, Марс Шабаев, Илдар Юзеев, Равил Фәйзуллин, Гәрәй Рәхим (поэзиядә); Зәйни Солтанов, Габдулла Шамуков (драматургиядә) үзләрен татар теленә

[15] Юсупов Р.А. Тәрҗемәнең теоретик һәм практик мәсьәләләре. – Казан: ТДГПУ, 2011. – 312 б.

[16] Юсупов Р.А. Тәрҗемәнең теоретик һәм практик мәсьәләләре. – Казан: ТДГПУ, 2011. – 312 б.

тәрҗемә итү осталары итеп танытaлар. 1960 еллар башына классик рус һәм совет әдәбияты әсәрләренең бик күбесе тәрҗемә ителә. 1990 еллардан башлап, илнең икътисади хәленә бәйле рәвештә, тәрҗемә эшчәнлеге сүлпәнәя төшкән.

Бөек рус язучысы һәм педагогы Лев Николаевич Толстойның Казан, татар халкы белән бәйләнеше шактый зур. 1841 елда Толстойлар гаиләсе Ясная Поляннадан Казанга күченә. Ул 1841-1847 елларда Казанда яши, Казан университетының философия һәм юридик факультетларында белем ала. Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов Указы белән 2018 ел Татарстан Республикасында Лев Толстой елы дип игълан ителде. Лев Толстойның яшьлек еллары Казанда үткән. Бабасының әтисе Зөядә гаскәр башлыгы булган. Булачак язучының бабасы граф Илья Толстойны 1815 елда ук Казан губернаторы итеп билгелиләр. Ул Химиклар мәдәният сарае паркы территориясендә, Кизич монастыре зиратында җирләнгән.[17]

Алга таба Л.Н.Толстой рус, бөтендөнья әдәбиятын баеткан роман, драма,
повесть, хикәя, истәлекләр һ.б. жанрлардагы әсәрләрен яза, педагогик эчтәлекле хезмәтләр, дәреслекләр тудыра. Лев Толстой гомеренең соңгы көннәренәчә үзен христиан дип атаса да, чиркәүгә каршы кискен фикерләре өчен Православ чиркәвеннән читләштерелгән була. «Толстовство» дигән үз христиан тәгълиматын булдыра. 1910 елның 7 ноябрендә Астапово станциясендә үлә. Язучының теләген истә тотып, аны соңгы юлга шулай озаталар. Толстой үлеме турындагы хәбәр яшен тизлегендә бөтен дөньяга тарала. Аның белән хушлашырга меңнәрчә кеше җыела. Үзе васыять итеп калдырганча, Ясная Полянада җирлиләр. Соңгы теләген истә тотып, Толстойның атын да шунда янәшәдә генә күмәләр.

Л.Н.Толстой Русиядә яшәгән төрле милләт халыклары язмышы, аларның матур киләчәге турында даими кайгыртып яшәгән затларның берсе булды. Әсәрләре Русиядәге бик күп милләт халыклары теленә дә тәрҗемә ителгән һәм әле дә тәрҗемә ителә. Танылган сүз остасының иҗаты белән татар укучыларын таныштыра башлауның йөз елдан артык тарихы бар. Әсәрләре татар теленә тәрҗемә ителгән әдипләрнең беренчесе И.А.Крылов, икенчесе Л.Н.Толстой була.

Әдип-педагогның балалар өчен язылган аерым хикәяләрен беренче тапкыр татар теленә XIX гасыр ахырында танылган мәгърифәтчеләр К.Насыйри, Т.Яхин һ.б. тәрҗемә итә һәм аларны үзләре төзегән төрле җыентыкларга, уку кулланмаларына кертәләр. XX гасыр башында исә бу изге гамәлләрне Г.Тукай, М.Мәрҗани, Н.Думави, Ф.Агиев һ.б. әдипләр дәвам итә. XIX гасыр ахырында Лев Николаевичның "Крейцер сонатасы", "Беренче шәрабчы" әсәрләре татар теленә тәрҗемә ителә, әмма аларны патша цензурасы басарга рөхсәт бирми. Беренче рус революциясе башлану белән (1905-1907 елларда), цензураның азмы-күпме көче кими, цензурасыз басу да гамәлгә керә. Шушы чорда Л.Н.Толстой әсәрләре дә татар телендә шактый күп басыла башлый.
1908 елда аның биш китабы, ә 1910 елда берничә әсәре татар телендә аерым китап булып дөнья күрә.
Октябрь борылышына кадәр бөек сүз остасының нинди әсәрләре тәрҗемә ителгән соң?

Шундый китапларның иң күренеклеләреннән Сәгыйть Сүнчәләй тәрҗемәсендә "Кавказ әсире" (1908), драматург һәм педагог Идрис Богданов тәрҗемә иткән "Корней Васильевич" (1909), "Крейцер сонаты" (1912), Сәгыйть Рәмиев тәрҗемәсендә "Тере мәет" (1911), Мәхмүт Галәү тәрҗемә иткән "Хаҗи Морат" (1913) һ.б. санала. Л.Толстойның Октябрьгә кадәр һәм аннан соң татар теленә тәрҗемә ителгән әсәрләренең шактый өлешен балалар өчен иҗат ителгән җимешләре тәшкил итә.

Татар әдипләре һәм тәрҗемәчеләре аның балалар өчен язган әсәрләрен аеруча яратып тәрҗемә иткәннәр. Бу өлкәдә бөек Г.Тукайның хезмәте гаять зур. Ул Лев Николаевичның шактый тирән эчтәлекле, тәрбияви кыйммәткә ия булган кыска хикәяләрен татар теленә тәрҗемә итә һәм аларны "Мәктәптә милли әдәбият дәресләре", "Яңа кыйраәт" исемле дәреслекләренә, өстәмә уку китапларына кертә. 1906 елда Г.Тукай "Фикер" газетасында

[17] Шифман А.И. Страницы жизни Л.Тостого.-Москва, 1983

Л.Толстойның сәяси эчтәлекле, башкорт җирләрен талау һәм башкорт халкының авыр хәле турында сөйләүче "Ильяс" хикәясен, шунда ук " Бик кыйбат" әсәрен тәрҗемә итеп бастыра.

1909-1913 елларда Л.Толстойның "Җиләкләр", дидактик эчтәлекле "Толстой хикәяләре", "Толстой бабай хикәяләре", "Тугрылыклы казый", "Ни чәчсәң, шуны урырсың", "Шайтан илә игенче", "Олылык нәрсәдә?" һ.б. китаплары татар телендә басыла.

Мәшһүр китап белгече, академик Әбрар Кәримуллин раславынча, 1905-1917 елларда Л.Н.Толстойның әсәрләре татар телендә 30 китап буларак дөнья күрә. 1908 елда аның биш китабы, ә 1910 елда берничә әсәре татар телендә аерым китап булып дөнья күрә.

Шунысы куанычлы: Октябрь борылышына кадәр татарлар Л.Н.Толстой әсәрләрен төрки халыклар арасында беренче булып үз телләрендә басу эшен башлап җибәргәннәр.

Октябрь борылышы бөек фикер иясенең күләмле әсәрләрен татар укучысына җиткерү мөмкинлеген тудырды. 1935 елда Сәрвәр Әдһәмова "Кавказ әсире", "Алпавыт иртәсе", "Балдан соң" әсәрләрен тәрҗемә итә. Фәтхи Бурнаш тәрҗемәсендә "Хаҗи Морат", Абдулла Әхмәт тәрҗемәсендә балалар өчен хикәяләр җыентыгы дөнья күрә. Күренекле язучы һәм тәрҗемәче Мәхмүт Максуд бөек рус әдибенең "Сугыш һәм тынычлык" эпопеясын, "Анна Каренина" романын зур осталык белән тәрҗемә итә. Афзал Шамов тәрҗемәсендә өч басмада "Яңадан туу" романы укучыга җиткерелә. Бөек талант иясенең "Казаклар", "Балачак", "Үсмерчак", "Егетлек" повестьларын татарчалаштырып, сәләтле тәрҗемәче Кыям Миңлебаев та изге гамәл башкарды.

Л. Толстойның Октябрь борылышыннан соң басылып чыккан 37 китабының унбишләбе балалар өчен иҗат ителгән. Алар арасында "Бульба" (Ш. Максутова тәрҗемәсе), "Бүре һәм кәҗә бәтие" (С. Сабиров тәрҗемәсе), "Ике иптәш", "Кечкенә хикәяләр", "Мәсәлләр һәм кыска хикәяләр", "Фил", "Хайваннар турында хикәяләр", "Хикәяләр һәм әкиятләр", "Әлифбадан хикәяләр", "Өч аю", "Нәниләргә" һ.б. җыентыклар бар. Бөек рус язучысының әсәрләрен татар теленә тәрҗемә итүгә Ә.Еники, А.Гыйләҗев, А.Гомәр, Ә.Камал, Ф.Басыйров, Ф.Фасеев кебек сүз осталары, тәрҗемәчеләре дә җитди өлеш керттеләр.

Аның кайбер тәрҗемә әсәрләре башлангыч сыйныф укучыларының Әдәби уку дәреслекләрендә дә урын алган. Мисалга “Слива төше” һәм “Зирәк чәүкә” хикәятләрен китерергә була.

Лев Толстойның бай әдәби мирасы, татар теленә тәрҗемә ителгән кыйммәтле әсәрләре татар укучысын, бигрәк тә яшь буынны гуманистик рухта тәрбиләүдә, аның эстетик зәвыгын баетуда бай чыганак ролен үти, кешелеклелек, югарый әхлакый сыйфатлар тәрбияләүгә этәрә. Дәреслек авторлары да юкка гына авторның мәсәлләренә һәм хикәяләренә мөрәҗәгать итмәгәннәр.

Гомумән, тәрҗемә әсәрләре укучыга белем, мәгълүмат биреп кенә калмый, матурлык хисе дә тәрбияли. Укучыны шул халыкның әдәбияты белән кызыксынуга да этәрә.

Билгеле, бу җаваплы эштә танылган мәгърифәтчеләр К.Насыйриның, Т.Яхинның, XX гасыр башы әдипләре Габдулла Тукай, М.Мәрҗани, Нәҗип Думави, һ.б. ларның олы хезмәтләре югары бәягә лаек.

Әлеге хезмәтне башкару барышында мин максатыма ирештем дип саныйм: Лев Толстойның татар теленә тәрҗемә ителгән бай әдәби мирасы белән таныштым ; тәрҗемә әсәрләренең максаты һәм әдәби тәрҗемәчегә куела торган таләпләр хакында теоретик белем тупладым. Әлеге эш мине бик күп укырга, эзләнүләргә этәрде. Бөөу фәнни эземне мин киләчәктә тагын да тулыландыра алам дип саныйм. Үзебезнең татар әдипләренең башка телләргә тәрҗемә ителгән әсәрләр белән дә танышасым килә. Кыскасы, әдәби тәрҗемәнең әдәбият белеме фәнендә олы хезмәт булуына сокландым.

Язучы-прозаик, әдәби тәрҗемәче Кыям Миңлебаев әдәби тәрҗемә хакында “Тәрҗемә – сәнгать ул!” дигән олы фикер әйтә. Әйе, тәрҗемә итү зур җаваплылык , осталык таләп итә. Төрле халык әдәбияты әсәрләренең татарча чыккан тәрҗемәләре әдәбиятыбызга алып килгән яңа темалары, идеяләре, аны жанр ягыннан баетуы, әдәби тәрҗемәләрнең шул чор рухын чагылдыруы белән кыйммәтле.

*Кулланылган әдәбият һәм чыганаклар:*
1. А.Г. Әхмәдуллин. Әдәбият белеме сүзлеге Казан: Татар. кит.
2. Даутов Р. Н. һәм Рахмани Р.Ф. Әдипләребез: биобиблиографик белешмәлек. 2 томда. Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2009.
3. Золотарёва И.В.. Михаилова Т.И. Поурочные разработки по литературе 10 класс. II полугодие издание 3-е, исправленное и дополненное. Издательство “ВАКО”
4. Сафиуллина Г.М., Хәсәнова Ф.Ф., Мөхәммәтҗанова Ә.Г. Әдәби уку. Казан. “Мәгариф-Вакыт” нәшрияты, 2014
5. Толстой Л.Н. Егетчак. Повесть. Таткнигоиздат. К. Миңлебаев тәрҗ. – Казан. 1977.
6. Шифман А.И. Страницы жизни Л.Тостого.-Москва, 1983
7. Юсупов Р.А. Тәрҗемәнең теоретик һәм практик мәсьәләләре. – Казан: ТДГПУ, 2011. – 312 б.
**8.** Интернет ресурслар:
http://www.belem.ru
http://www.wikipedia.ru

## ГӨЛСИНӘ ГАЛИМУЛЛИНАНЫҢ “ТОМАНЛЫ ТӨН” ӘСӘРЕНДӘ ОБРАЗЛАРНЫ БИРҮДӘ АВТОРНЫҢ ТЕЛ – СУРӘТЛӘҮ ОСТАЛЫГЫ

*Маканова Эльвина Альфред кызы, 8 нче сыйныф укучысы Фәнни җитәкче:*
*Маркелова Ләйсән Гарәфи кызы,*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы*
*МБГБУ “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы*
*Иштуган урта гомумбелем бирү мәктәбе”*

Саба районы үзенең гүзәл табигате, хәтфә болыннары, урман –күлләре, тырыш, уңган, хезмәт сөючән халкы белән данлыклы. Саба ягы гасырлар буена төрле һөнәр ияләре белән дан тоткан. Ата –бабаларыбызның күркәм эшләре һәм тырышлыклары нәселдән – нәселгә күчеп дәвам итә.

Безнең район – күренекле шәхесләр тудыручы, үстерүче төбәк. 7 якташыбыз – академик Әбрар Кәримуллин, СССРның халык артисты Шәүкәт Биктимеров, композиторлар Рөстәм Яхин, Хөснул Вәлиуллин, Фасил Әхмәтов, музыка белгече Мәхмүт Нигъмәтҗанов, рәссам Тавил Хаҗиәхмәтов Татарстан Республикасының иң олы бүләгенә – Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек булдылар. Күренекле фән эшлекләләре Азат һәм Ринат Әхмәдуллиннар,Алмаз Ахунҗанов,Марат Гыймадиев, Әлфия Ибраһимова, Рифат Сверигин, Мөхәммәтвасил Зарипов, Дөрия Рамазанова, Билал Минһаҗев Саба районы шәхесләре.

Саба төбәге гомер – гомергә үзенең язучылары һәм шагыйрьләре белән горурланып яши. Җамалетдин әс – Сабави(1780-1866), Камалетдин Болгари(1796-1833), Габделмәннан (1858-1908),Солтан Рахманколыйлар(1888-1916) башлаган иҗат традицияләрен Мәгъсум Хуҗин, Газиз Нәбиуллин, Фәүзия Бәйрәмова, Заһирә Гомәрова, Зөфәр Шәйхетдинов кебек Язучылар берлеге әгъзалары дәвам итте. Күп еллар районыбыз газетасы “Саба таңнары”н җитәкләгән Тәлгат Нәҗмиев көлеп – шаярып, туган – яшәгән төбәгенең кызыклы кешеләрен зәвык белән бәян итеп, Саба якларының тарихын язды, энциклопедиясен төзеде.

Бүгенге көндә каләм тибрәтүче шагыйрьләрдән Миңнегөл Манихова, Ильмира Гыймаева, Тәслимә Низами, Рөстәм Зарипов, проза өлкәсендә Гөлсинә Галимуллина исемнәре барлыкка килде. Гөлсинә Галимуллина биш ел вакыт эчендә, ун китап язып бастырып, тиз арада халык арасында популярлык казанды.

Сыйныфтан тыш уку дәресендә татар теле һәм әдәбияты укытучыбыз якташыбыз Гөлсинә Галимуллина иҗатына күзәтү ясап, китаплары белән таныштырды. Хәзерге вакытта укытучым авторның китапларына корректор вазифасын башкара. Укылган китаплар буенча

фикер алышып, тәэсирләрне уртаклаштык. Минем үземә бу китаплар арасыннан иң ошаганы – “Томанлы төн” повесте. Гөлсинә Галимуллина китапларында сурәтләнгән вакыйгалар безнең якларда бара, ә геройлар безнең арабызда яши бит.

**Эзләнү-тикшеренү эшенең объекты:** Гөлсинә Галимуллинаның “Томанлы төн” повесте

**Теманың актуальлеге:** Якташ язучыбыз Гөлсинә Галимуллина китаплары киң катлам укучылар тарафыннан яратып укыла. “Томанлы төн” әсәрендә тормышта булган проблемалар күтәрелә, тормышчан вакыйгалар яктыртыла, геройлар үз тирәбездә яши.

**Эзләнү – тикшеренү эшенең максаты:**“Томанлы төн” әсәренең төзелешен, образлар бирелешен, тел – сурәтләү чараларын анализлау, нәтиҗәләр ясау.

**Эзләнү – тикшеренү эшенең бурычлары:**

1)Язучының тормыш юлы белән тирәнрәк танышу;

2) Сурәтләнгән вакыйгаларның чынлыгына ышандыру көчен аңлау;

3) Образларга характеристика бирү;

4) Әсәрнең телен, сурәтләү чараларын тикшерү;

5) Башка китап укучыларның фикерләрен барлау;

6) Язучының укучыларына әйтергә теләгән фикерен ачыклау.

**Эш алымнары:**Әсәр белән танышу, китапны игътибар белән анализлау, тел – сурәтләү чараларын туплау, китапны укучыларның фикерләрен барлау, язучы белән очрашу.

**Көтелгән нәтиҗәләр:**

- Безнең эзләнү эшебез дәресләрдә файда китерердәй мәгълүмат булып тупланууы күз уңында тотыла.Мәктәпне тәмамлап, зур тормышка аяк баскан һәрбер укучы кайда гына булса да, якташыбыз иҗаты белән кешеләрне таныштыра, кызыксындыра алырга тиеш.
- Мөстәкыйль рәвештә укылган әсәрләрне анализларга һәм нәтиҗә чыгарырга өйрәнү.

Якташыбыз Гөлсинә Галимуллина Мишә елгасы буена урнашкан матур табигатьле Эзмә авылында биш балалы гаиләнең беренче баласы булып дөньяга килгән. Әтисе Наил абый гомере буе механизатор булып эшләп, заманында Татарстан АССР Югары Советы депутаты булып торган, укымышлы, аңлы кеше булган. Үзенең җиде буын нәсел тамгасын белә. Әнисе авылның уңган, тырыш, чибәр, ихтирамлы хатын – кызы.Иң олы кыз буларак Гөлсинә әнисенең уң кулы, эне-сеңелләренең яраткан апасы булып, мәктәптә яхшы укуы, барлык пионер эшләрен башлап йөрүе, активлыгы белән аерылып торган. Шәүкәт Галиевның шигырьләрен сәхнәдән бик оста сөйләгән. Китап укырга яраткан. Кечкенәдән үзенең фикерләрен кәгазьгә төшереп,журнал –газеталарның актив хәбәрчесе булган. “Миндә китапка, әдәбиятка мәхәббәт уятучы,гел үсендереп торучы татар теле, әдәбияты укытучысы Мәдинә апа Исламова булды” – дип искә ала Гөлсинә апа Галимуллина. Башта Эзмә, аннары Шәмәрдән мәктәбен тәмамлаганнан соң, Казан дәүләт университетының журналистика бүлегенә укырга керә. Укып бетергәч, яшь журналист районыбызның ул вакытта “Җиңү байрагы”(хәзер “Саба таңнары”) газетасына эшкә билгеләнә. Гөлсинә Галимуллина 1978 нче елдан башлап, 35 ел буе газетаның авыл хуҗалыгы бүлегендә хезмәт куя. Утыз биш елдан артык редакциядә эшләү дәверендә Саба районында ул яктыртмаган проблема, ул булмаган колхоз, ул кермәгән йорт калдымы икән...Тәҗрибәле журналист халыкның уй-фикерләрен, теләк-хыялларын сизгер тоя, язмалары аша шул теләкләрне тормышка ашыра. Шуңа күрә туган ягында Гөлсинә Наил кызын ихтирам итәләр, яраталар да. 2007нче елда җирле теманы яктыртучы иҗатчылар бәйгесендә җиңеп, Татарстан журналистларының иң зур бүләген – “Бәллүр каләм” призын яулаган. 2009нчы елда “Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре” дигән мактаулы исемгә лаек булган. Татар әдәбияты дөньясына Гөлсинә Галимуллина журналистикадан килеп кергән. Күп иҗатчылар өчен бу – табигый күренеш.Бүгенге әдипләрнең кайсын гына карама – һәммәсе дә диярлек көндәлек журналистика һәм публицистика белән шөгыльләнә. Шунсыз мөмкин дә түгелдер. Җәмгыятьнең бүгенге борчу – мәшәкатьләрен, янәшәдәгеләрнең көндәлек проблемаларын үз йөрәге аша уздырган, төрледән – төрле язмышлы кешеләр белән даими аралашып торган

иҗатчы гына чын мәгънәсендә тормышчан әдәби образлар тудыра, укучыларның күңел түренә барып җитә ала. Гөлсинә Галимуллина да әнә шундыйлардан.Матур әдәбияттагы беренче әсәрләре белән үк ул үз укучысын тапты. Бу язмаларда – тормышның бормалы бусагалары, бүгенгенең ачы чынбарлыгы, гыйбрәтле язмышлар, кызыклы характерлар. Бу әсәрләр кемнедер кеше яшәешенең максаты турында фәлсәфи уйлануларга, кемнедер үзе өчен дә көтелмәгән кыю адым ясарга этәрә, кемнедер тормышында ялгышлыктан саклап кала. Бу әсәрләрдән бер үк вакытта җитдилек тә, самимилек һәм эчкерсезлек тә бөркелеп тора. Әдибәбез бигрәк тә хатын –кыз образларын оста ачып бирә. Аның геройлары – тормыш авырлыклары алдында югалып калмаучы кыю характерлы асыл затлар. Татар милләтенең идеалы булырдай хатын – кыз образларын нәкъ менә Гөлсинә Галимуллина әсәрләреннән эзләргә кирәктер. Гөлсинә Наил кызының татар хатын – кызының гаиләсе, балалары хакына тормыш мәйданындагы көрәшен чагылдырган, хисләргә, матур образларга бай, шул ук вакытта тирән эчтәлекле һәм җитди фикерле “Мәхәббәт аланы”, “Ак бураннар аша”, “Күгәрчен оя корганда”, Томанлы төн”, “Карлы миләш тәме”, “Ефәк кулъяулык”,”Алтын ачкыч”, “Ай күлгә сыенганда”, “Җиләкле тау сере”,”Тау җылысы” повестьлары милләттәшләре һәм киң катлау укучылар тарафыннан яратып кабул ителде.

“Томанлы төн”повестенда һәрберебез йөрәге аша үткән яки үтәргә мөмкин булган хәлләр тасвирлана. Тормышта язмышлар төрле – төрле булган кебек, бу әсәрдәге геройларның уй - кичерешләре, эш – гамәлләре, мәхәббәт – нәфрәтләре, табу – югалтулары, үкенү – тетрәнүләре үзләренә генә хас кичерешләр аша бирелә. Районыбызда яшәп иҗат итүче Гөлсинә Галимуллинаның “Томанлы төн” повесте бүгенге заман кешеләренең уй – хисләрен, үзара мөнәсәбәтләрен, сөю – сөелүләрен, әхлакый сыйфатларын чагылдыра. Мавыктыргыч сюжетка корылуы, теленең образлылыгы, халыкчанлыгы бер сулыш белән укылышлы итә.

“Томанлы төн” повестенда берьюлы берничә **проблема** күтәрелә. Бу – олы мәхәббәт, хыянәт, үкенечле язмышлар, түрәлек.

Әсәрнең **сюжет** төзелеше гади.

**Башлам.** Сәяф Замановның “Көмеш тун” комбинатына җитәкче итеп билгеләнүе. ( I – III бүлекләр)

**Төенләнеш.** Сәяф Замановның бозык хатыннар кармагына эләгүе. ( IV - V бүлекләр)

**Вакыйгалар үстерелеше.**Рәйфәнең берүзе тормыш арбасын тартуы. ( V – VI бүлекләр)

**Иң югары нокта.**Сәяф Замановның төрмәгә эләгүе һәм үлеме. ( VI – VII бүлекләр)

**Чишелеш.** Рәйфәнең бәхетен табуы. ( VIII - X бүлекләр)

Китап авторы сюжет сызыгын катнашучыларның эш – гамәлләренә таянып, аларның хисләрен хәрәкәттә, тормыш шартларына бәйләп, үзара мөнәсәбәтләрен чагылдырып, мавыктыргыч итеп ачып бирә.

“Томанлы төн” повесте Сәяф Замановның Кызылъяр районының данлыклы “Көмеш тун” күн комбинатына җитәкче итеп сайлануы, әнисенең каберенә килеп шатлыгын уртаклашуы белән башланып китә. Сәяф йөрәк әрнүе белән “Әни, бүген миңа синең акыллы киңәшләрең, җылы сүзең кирәк”-дип өзгәләнә. Яшьли ятим калгач, аталары Мансур апасы белән икесен, өйләнмичә, булдыра алган кадәр кадерләп үстерә. Авыл кызы Рәйфәгә өйләнеп, алар матур тормыш корып җибәрәләр. Бар да җиткән, ике катлы йорт, абзар тулы мал – туар, үзләренең пай җиреннән гадел хезмәт белән алган уңыш. Яннарында акыллы киңәшләрен биреп торучы әтиләре, инсафлы кызы белән улы. Бәхетле булу өчен бар да җиткән. Ләкин Сәяфнең дәрәҗәле урынга куелуы белән тормыш йомгагы чуала башлый. Томанлы тормыш кайчан башланды соң? Күрше кызының рәнҗүле күз яшьләреннән соңмы? Әллә яратып өйләнгән Рәйфәгә бозык хатыннар белән хыянәте аркасындамы? Башта Сәяфнең эшләре гөрләп бара. Бу уңышлар аның башын әйләндерә шул. Аның “Мин үзем Аллаһ”-дип тәкәбберләнүе, миллионлаган хәрәм акча артыннан чит илләргә йөрү, кәеф – сафа кору – аны текә яр

кырыена китереп тери. Хатыны, этисенең Сәяфне ялгыш адымнан саклап калырга тырышулары нәтиҗәсез кала. Җинаять эше ачыла, бөтен гаепне аңа тагып, төрмәгә утырталар. Төрмәдә уйланырга вакыт күп. Камерадашы Разат белән сөйләшеп, кылган эшләренә үкенеп, иманга килеп, намазга басалар. Сәяф иреккә чыккач, тормышын өр – яңадан башларга хыяллана. Ләкин йөрәге чыдамый, аңа инсульт була. Баһадир гәүдәле Сәяфне туган җиренә алып кайтып җирлиләр. Иренең “кара эшләре”ннән күп миллионлаган бурыч хатыны Рәйфә җилкәсенә кала. Бу хәсрәт улы артыннан этисен дә алып китә. Шәфкать туташы булып эшләүче Рәйфәне бу кайгылар сындыра алмый. Ул үзендә авыр сынауларны җиңеп чыгарлык көч таба. Рәйфәнең юлында, хатыны юл фаҗигасендә һәлак булган олы йөрәкле ир- ат Замир очрый. Аның өчен томанлы төн тәмамлана, кояшлы көн башлана.

Автор үзенең геройларына сыйфатлама биргәндә аларның портретларын, язмыш – тормыш тәртибен, үз – үзен тотышын, эш – гамәлләре аша холкын, карашларын, фикерләрен оста итеп тасвирлый алган. Геройларына җисеменә ярашлы исемнәр биреп, характерларын тулырак ачарга тырышкан.

Ил күләмендә соңгы егерме – утыз елда барган зур үзгәрешләр җәмгыятькә бик күп каршылыклар китереп чыгарды. Кемнәрдер властька килеп баедылар, кемнәрдер шул байлыкларның корбаны булдылар. “Томанлы төн” әсәренең төп герое булган **Сәяф** образы шул заман кешесе итеп бирелә. Автор аның фамилиясен Заманов дип куеп шуңа ишарәли. Кылыч белән коралланган дигән мәгънәне белдерүче Сәяф исемен әти – әнисе аңа яратып кушкан. Бик яшьтән әнисез калган малай этисе тәрбиясендә үсә.Гомер юлында кешеләрнең кемлеген аңламыйча ялгышуы - ана назы, әни тәрбиясе җитмәүдән булырга да мөмкин. “Дин – агу”дигән чорда үскән Сәяф, властька ия булгач, “Мин үзем Аллаһ Тәгалә”дип әйтергә дә курыкмый. Дөньяда гадел, аек акыл белән яшәгән этисенең, хатыны Рәйфәнең тырышлыкларына карамастан, кара портфелен кочаклап, тайгак хыянәт юлына кереп адаша. Сәяфне фаҗигага китергән сәбәпләр берничә төрле. Беренчесе, яхшы белмәгән кешеләргә ышану булса, икенчесе – тәкәбберлек. Өченче сәбәп – хәрәм акча. Кайда акча, шунда хыянәт, дип бик дөрес әйтәләр. Сәяф беркатлылыгы белән, үзе дә аңламыйча, җинаятьчел дөньяга килеп эләгә. Төрмәдә, соңарып булса да, гөнаһларын юарга тырыша. Тормышын яңадан башларга өлгерә алмый, йөрәге чыдамыйча вафат була, туган җиренә үле гәүдәсе генә кайта. Гомеренең соңгы елларында томан арасында калып адашкан Сәяф тә, миллионнар артыннан куып, аның корбаны була.

**Рәйфә** исеменең мәгънәсе – яратучы, бик мәрхәмәтле, игелекле, кайгыны уртаклашучы, кызганучан. Автор аны кояш кебек сары чәчле, зәңгәр кыңгырау чәчәккә охшаган күк күзле, җылы күңелле образ итеп сурәтли. Гел уйлары белән яктыга – кояшка үрелүче чәчәк кебек хатын – кыз. Аның максаты – матур итеп тормыш итү, бәхетле булып яшәү. Ул – табигать баласы. Авыл җирендә яшәп, бөтен тырышлыгы белән йорт – җирне алып бара, яратып маллар карый, умарталар тота. Бакчасы чәчәкләргә күмелгән, помидорлар, карбызлар, чук кебек тезелгән кыярлар үстерә. Әсәрнең буеннан буена Рәйфәне чәчәкләр озата килә. Ул туган ягының ямен, күркәмлеген тоеп яши. Гаилә - аның өчен изге урын.Сәяф белән булган тормышы табигатьнең матур төсләре, гөл – чәчәкләр, җирнең саф исләре белән бәйләп сурәтләнә. Ап – ак күңелле, ак халатлы Рәйфә хастаханәдә эшли. Үз эшен яратып эшләүче шәфкать туташын авырулар сагынып көтеп алалар. Хезмәтеннән ләззәт табып, яраткан кешесенең җылысын тоеп яшәүче Рәйфәдән бәхетле хатын – кыз юк. Ләкин тормыш давыллары өермәсе барлык хыялларын җимереп ташлый. Инде түзәр чама калмады дигәндә дә, ул яхшыга өметләнә. “Саф йөрәкле алиһә”-ди аның турында автор. Әйе, аның алдына зур сынаулар куела. Авыр вакытларда якыннары, балалары акыллы киңәшләр белән ярдәмгә килә. Рәйфә барлык киртәләрне җиңеп чыгучы, сабыр, түзем, көчле хатын – кыз итеп бирелгән.

Әсәрдә авторның бик яратып сурәтләгән **Мансур карт** образы бар. Мансур исеме җиңүче дигәнне аңлата. Сәяфнең атасы – авылның мөхтәрәм карты. Гомере буена гадел хезмәт итеп, мактаулы исемнәр алган гади җир кешесе.Төрле хәлләрдә дә сабыр булып кала белә. Мансур яшьтән тол калып, хатыны рухын рәнҗетүдән куркып, балаларын ялгызы

үстерә. Киңәшләре белән кешеләргә үрнәк булып торырлык образ итеп бирелгән. Иң авыр вакытларда ул зиратка яраткан Зөбәрҗәте янына киңәшкә бара, җаны бәргәләнә башласа, иген басуларына чыга. Килененә тормыш алып барырга булыша. Улы Сәяфнең ялгыш юлдан китүенә бик борчыла: “Тормыш – әкият түгел. Һәр ялтыраган алтын, һәр җемелдәгән йолдыз булмый. Мин сиңа балачактан ук бары тик яхшы, изге уйлар уйларга өйрәттем бит”- дип аңлатырга тырыша. Үләр алдыннан йортына хатын –кыз җылысы алып килгән шәфкатьле килененә: “Минем ялгышымны кабатлама, синең кебек гүзәл холыклы, тырыш хатын – кызны бәяли белүче ир солтаны табылыр, ялгыз калма”- дип әйтергә үзендә көч таба.

“Томанлы төн” әсәрендә автор тарафыннан бик яратып сурәтләнгән тагын бер образ – **Гадилә апа** образы бар. Гадилә – гадел, намуслы дигән мәгънә аңлата. Ул – Рәйфәнең яраткан укытучысы. Ул хәзер дә аның белән аралашып, тормышта булган проблемаларын, шатлыкларын уртаклаша. Гадилә апаның холкында бер сыйфат бар: ул укучыларының начар якларын ишетсә, гаепне үзеннән эзли. “Тиешле тәрбия биреп җиткермәгәнбез,”-ди ул, укучысының яшүсмер вакытларын хәтерендә барлый башлый. Ләкин һәрчак аларның яхшы якларын исенә төшерә. Шыксыз көзнең дә матурлыгын күрә белүче, һәр кешегә яхшылык теләүче бу мөгаллим укыткан укучылары белән чиксез горурлана. Шуңа күрә дә күптән мәктәпне бетергән олы – олы дәрәҗәле укучылары аның янына килеп, сөенечләрен, кайгыларын уртаклашалар. Аның белән бер сөйләшеп утыру да тормыш мәктәбе дәресен тыңлаган кебек файдалы.Үзенең укучыларын китап яратырга өйрәтүче Гадилә апа: “Алтын хәзинәсе бер көнлек, белем хәзинәсе мәңгелек”- дип әйтергә ярата.

Әсәрдә исем мәгънәсе җиңел дигәнне аңлата торган **Ясирә** образы, чыннан да, җиңел холыклы, бозык хатын итеп сурәтләнгән. Гаиләле, елан телле бу хатын беркатлы бай җитәкче Заманов белән танышкач, аны төрле бозымнар белән үзенә карата. Рәйфә иренең кесәләреннән шикле әйберләр таба, үзе дә чирли. Динсез, әхлаксыз әнисенең кыланмышларын күреп үскән Ясирә кесәсе калын ирләрне ничек кармакка эләктерү юлларын яхшы белә.Ялган иминиятләштерү компаниясе төзеп, бәхетле киләчәк вәгъдә итеп, акчалы ирләрне аздырып йөри һәм максатына ирешә. Сәяфнең да гаиләсен җимереп, төрмәгә кертә. Әсәрнең ахыры бик гыйбрәтле – Ясирә яман чир белән авырып, хастаханәдә ята, ул ялгыз. Балалары белән ире кая? Бу тискәре геройның язмышы шулай тәмамлана. Китап авторы байлык җыю максатыннан теләсә нинди түбәнлек, ялганнарга барган Ясирә образы аша җәмгыятебездәге кешелек кыйммәтләренең начарлануы аркасында хатын – кызның әхлаксызлана, кадерсезләнә баруын ачык күрсәтүгә ирешә.

Повестьта ярдәмче образлар күп. Аларны кыскача характерлау таблица формасында бирелә.

| **Образның исеме** | **Аның чыгышы, шөгыле** | **Үзенчәлекле сыйфатлары** | **Автор кулланган тел – сурәтләү чаралары** |
|---|---|---|---|
| **Илүс** | Сәяф һәм Рәйфәнең уллары, һөнәре буенча - адвокат | Нык ихтыярлы, тәрбияле, акыллы | Чын ирләр тавышы белән җавап бирә, төптән уйлый белә |
| **Илүсә** | Сәяф һәм Рәйфәнең кызлары,булачак хисапчы | Максатчан, эчкерсез күңелле | Зур кара күзле, үткен карашлы, спортчыларныкы кебек төз гәүдәле |
| **Айзирәк** | Сәяф һәм Рәйфәнең күршеләре | Нечкә күңелле, ышанучан, гади, | Вөҗданы пакь,йөзе ак, тырыш кыз, ипле, йомшак тавышлы |
| **Алтынбикә** | Сәяф белән Рәйфәнең күршеләре | Зирәк, сабыр холыклы, тугрылыклы | Төз, кызлар кебек җыйнак гәүдәле,ак күңелле, самими җанлы |
| **Гадилә** | Рәйфәнең укытучысы, лаеклы ялда | Намуслы, чиста күңелле, тыныч холыклы,шигъри җанлы | Чын укытучы, тормыш мәктәбе дәресе бирүче |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **Разат** | Сәяф белән төрмәдә бер камерада утыра | Дини, сабыр, акыллы | Шифалы догалары белән булышучы |
| **Замир** | Рәйфәнең танышы | Максатчан, ышанычлы ир –ат, бәхетле киләчәк вәгъдә итүче | Юаш малай кебек карап тора, мәчет сала – игелекле эш башкара |
| **Камилә** | Рәйфәдә дәвалана, авыл фельдшеры | Эшчән, гади, тырыш, эчкерсез | Шомырттай кара күзле, катлаулы язмышлы кеше, нәфис, затлы, чибәр ханым |
| **Илһам Сәлимович** | Рәйфәнең хезмәттәше, табиб | Тыныч холыклы, сабыр кеше | Артык нечкә күңелле, илтифатлы, үз эшенә бирелгән |
| **Солтангәрәй** | Хастаханәдә дәваланып ятучы бабай | Тормыш авырлыкларына бирешмәгән зирәк карт | Дәрәҗәле кеше, олы максат куеп эшләгән җир кешесе |

Язучы кеше образлары бирү белән генә чикләнмичә, символ образларны да уңышлы куллана.Әсәрнең исеме дә символик мәгънәгә ия.

Әсәрнең төп сюжетына ияреп баручы **томан** - символик образ. Сәяфнең тормышы гел томан эчендә кебек тоела. Томанлы төн, ап –ак томанга төренгән караңгы төн, томанлы төнне ерып машина алга ыргылды, тормышыңны томанлы төнгә әйләндереп, чыга алмыйча адаша күрмә, юлга томан төшкән, бөтен дөньяны томан басты. Сәяф томанлы төндә адашып кала, яшәлгән гомере томанлы төн кебек, Рәйфәнең тормышы: артта томанлы төн,алда кояшлы көн.

Әсәрнең буеннан буена Рәйфәне чәчәк озатып бара.**Чәчәк** – символик образ.Болындагы чәчәкләр, күзләре кыңгырау чәчәге кебек, бакчасы тулы чәчәк, соңыннан аны кулына чәчәк тоткан ир бәхетле итә.

**Ак алъяпкыч** – үзенчәлекле образ – символ.Аны Сәяфнең әнисе үз куллары белән тегеп кигән булган. Әнисе исән вакытта аш – су әзерли, Рәйфә килгәч тә, гаилә бәйрәмнәрендә биленә бәйләргә ярата – кадерле гаилә ядкаре. Алъяпкыч – буыннар арасындагы бәйләнешне тотып торучы истәлек.

**Кара портфель**. Миллионнар салынган кара портфельне Сәяф бер дә кулыннан төшерми.Портфельнең кара төсе Сәяфне адаштырган кара фаҗига билгесе.

Әсәрдә төш күрү, төшне юрау, төшләрнең чынга ашу мотивлары бар. Автор төшләргә аерым вазифа йөкли, аларның нигезендә җирдәге тормышның вакытлы гына булуы, фани дөньяның бакыйлык белән бәйләнеше турында төшенчә ята. Геройлар күргән төшләр чынга аша. Мәсәлән, Рәйфәнең Сәяфне ярның икенче ягында күрүе аларның мәңгегә аерылышуы белән тәмамлана.

Повестьта ырым – ышанулар, сихер – бозымнар, күз тию кебек күренешләр дә урын алган. Автор дини күзлектән чыгып, сихер белән шөгыльләнүчеләрнең иң гөнаһлы кешеләр икәнлеген искәртә. Ә инде татар халкында борынгыдан килгән ышанулар, ырымнарны онытмаска, киләчәк буынга тапшырырга чакыра. Мәсәлән, балага күз тисә, тәрәзә пыяласының пар – су тамчылары белән, бисмилланы әйтеп, бит – күзләрен сөртергә кирәк.

“Томанлы төн” әсәренең теле гади, халыкчан, образлы әйтелмәләргә бик бай. Гөлсинә Галимуллина тел – сурәтләү чараларын оста файдалана, сүзләргә тылсымлы канатлар куя. Язучы хисләрне тулы итеп белдерергә мөмкинлек бирүче телебезнең байлыгы булган матур җәүһәр сүзләрен эшкә җигә. Ул һәр сүзнең асылын, мәгънәсен сизгер тоя белә.Вакыйгаларны, геройларның сөйләмен образлы, бизәкле, тәэсирле итә торган сурәтләү чаралары – метафоралар, эпитетлар, фразеологик әйтелмәләр, чагыштырулар, мәкаль һәм әйтемнәрне яратып һәм мул куллана. Тикшеренү эше барышында без моны исбатлый алдык.

**Фразеологик әйтелмәләр.**Күңелгә авыр алу, йөзенә бәреп әйтү, миен ашау, йөзгә оятлык китерү, тел тидерү, башын әйләндерү, авызын җыя алмау, күңеленә юл табу, башын

бутау, күңелен төшерү, хәленнән килү, акчасын җилгә очыру, якты дөнья белән хушлашу, корсагы шиңү, рухын күтәрү һ.б.

**Чагыштырулар.** Сыгылган лимон кебек эшләү, энҗе бөртегедәй күз яше, күз карасыдай саклау, сүзе йөрәгенә ук кебек кадалу, пар күгәрченнәр күк яшәү, көзән җыергандай куырылу, шомырттай кара күз, чишмә суы кебек аккан яшь, күз карасыдай үстергән кыз, балалар кебек елау һ.б.

**Метафоралар.** Йөрәк җимешләре, тимер рәшәткәле йорт, мәхәббәт диңгезе, туганда маңгайга язылган сынау, ал төсләрдән торган тормыш, бәгырьгә ук булып кадалган, гомер баскычы, тормыш китабы, намазга басу, хәсрәт эчендә дөрләп янган йөрәк, тормыш юлы, гомер баскычы, мәхәббәт диңгезе һ.б.

**Эпитетлар.** Баһадир гәүдәле ир, кайнар яшь, акыллы киңәш, ачулы караш, җылы сүз, бәхетле балачак, татлы мизгел, ак күңел, иманлы йөз, ягымлы чырай, кадерле вакыт, ягымлы тавыш, бәхетле киләчәк, ялкынлы күз, каткан күңел,саф язмыш, хыялдагы йорт, авыр уй, салкын акыл, гаярь ир, авыр тынлык, акыллы күз, алтын йөрәкле хатын һ.б.

**Мәкаль һәм әйтемнәр.** Байлыгың җилдән килсә, тормышың давылга очар. Еланның агуы телендә, яманның ачуы күңелендә.Алтын хәзинәсе бер көнлек, белем хәзинәсе мәңгелек. Кояш чыкса табигать яңара, китап укысаң күңел агара.Туган илең – туган анаң, чит ил – үги анаң.Җиреннән аерылган җиде ел елар, иленнән аерылган үлгәнче елар. Акчаң беткәнгә кайгырма, көчең белән эшең бетмәсен.Күрше хакы – Алла хакы. Кеше сүзе кеше үтерә.

| | | |
|---|---|---|
| **Фразеологик әйтелмәләр** | **234** | Сәяф кетәклектә утырган тавыкларга сәлам бирә, оя тулы йомыркаларга күз ташлый. |
| **Чагыштырулар** | **54** | Рәйфә стеналарын юып, ягып җибәрүгә, бер сәгать эчендә мунча май кебек булды. |
| **Метафоралар** | **88** | Бала – бәгырь җимеше, кодага игътибарлы булыгыз!(Рәйфәнең әнисе) |
| **Эпитетлар** | **87** | Йөрәккә җыйналган авыр сагышны күз яшьләре аша юып төшердем.( Камилә) |
| **Мәкаль һәм әйтемнәр** | **33** | Һәр ялтыраган алтын булмас, һәр җемелдәгән йолдыз булмас. (Мансур карт) |

Эзләнү эшеннән күренгәнчә, әсәрдә автор кулланган сурәтләү чаралары кеше күңеленә көчлерәк тәэсир итү өчен булыша. Алар һәр образның, вакыйгаларның нечкәлекләрен тоеп, гүзәл һәм камил сәнгать әсәре буларак кабул итү, аңлау өчен хезмәт итә. “Томанлы төн” әсәре бүгенге заманның тормышчан, ышандырырлык вакыйгаларына нигезләнеп иҗат ителгән. Анда һәрбер образ үзенчә сабак бирә, укучының күңелен тәрбияли. Кайсы чорда яшәсәк тә, хатын – кыз язмышы, гаилә мәсьәләләре актуаль тема булып кала. Татар әдәбияты хатын – кыз образларына ярлы түгел. Классик язучыларыбызның төрле елларда иҗат иткән күңел тойгыларына бай, рухлары белән көчле булып истә калган татар хатын – кызлары янына Гөлсинә Галимуллина тудырган Рәйфә образын өстәргә мөмкин. Чөнки ул мөлаемлеге, сүзгә тапкырлыгы, эчкерсезлеге белән безнең рухи дөньябызны баета, күңелләрне сафландыра, канатландыра. Авыр сынаулар алдында сыгылып төшмичә, тормыш арбасына җигелеп тарта башлаган хатын күзгә күренмәс җепләр белән укучы йөрәгенә тоташа. Ул безнең тирәлектәге халыкның үз баласы, үз каны, үз хәсрәте. Әсәрдә Рәйфә тормышының кискен борылышларында югалып калмавы, аның тирә – юньдәгеләргә үтә сизгер, нечкә күңеллелеге, мәрхәмәтле була белү сыйфатлары белән якын. Вакыйгалар барышында автор үзенең яраткан героен бик авыр сынаулар: гайбәт- ялганнар, яраткан иренең хыянәте, төрмәдә – үлеме, ялгышлары аркасында тау кадәр бурыч белән калу белән сыный. Рәйфә, барысын да җиңеп, үзенең бәхетен таба, чөнки ул моңа бик тә лаек. Әсәрдә Рәйфә – җиңүче, бүгенге заман татар хатын – кызларының әхлакый өлгесе. Иңнәр сыгылырлык авырлыклар килгәндә гаиләсенә терәк, газиз балаларына акыллы киңәшләр

бирерлек баһадир гәүдәле Сәяф тормыш сынаулары алдында җиңелде. Чөнки ул булганына шөкер итеп яши белмәде. Гаилә җылысын, әтисен, хатынын, балаларын, мәхәббәтен читләргә алыштырды, алар каршындагы изге бурычын онытты.

Язучы үзенең әсәрләрен оптимистик рухта тәмамларга ярата. "Томанлы төн" китабын ябып куйганда авторның "Җирдә бәхетсез кеше юк, бәхетенең кадерен белмәүчеләр генә бар" дип нәтиҗә ясыйсың.

21нче гасыр башы безгә бик күп үзгәреш, яңарыш, яңа технологияләр алып килсә дә, рухи кыйммәтләргә тиң – тәңгәл бәяләр әлегә юк. Рухи кыйммәтләрнең бәхәссез өстенлегенә ирешүдә әдәбият, китапның өлеше әйтеп бетергесез зур. Соңгы елларда әдәби сүзнең, китапның абруе төшсә дә, әле бу рух көчсезләнгән дигән сүз түгел. Моның дөреслегенә мин интернетта утырганда, "Мой мир", "ВКонтакте" социаль челтәрләрендә язылган фикерләр белән танышканнан соң ныграк ышандым."Томанлы төн" китабын укучыларның авторга язган хатларыннан өзекләр китереп үтәргә телим.

| ***Наилә Шәрифуллина, Әтнә, 45 яшь*** | ***Әлфия Мөкминова, Бөгелмә,***<br><br>***36 яшь*** | ***Дания Әфләтунова, Сургут,***<br><br>***50 яшь*** | ***Резеда Фәррахова, Алабуга,***<br><br>***29 яшь*** | ***Гөлнур Кадыйрова, Аксубай,***<br><br>***55 яшь*** |
|---|---|---|---|---|
| "Сезгә рәхмәтемне җиткерәм. Тирән мәгънәгә ия, күңелгә ятышлы әсәрегезне укып чыктым. Безнең хәзерге яшәеш...Соклан ырлык татар кызы..аның балалары...Уй – кичерешләрне әйтеп бетерә торган түгел. Рәхмәт сезгә, Гөлсинә апа, шундый матур әсәрләр тудырып безне куандырган өчен." | "Шул кадәр тирән эчтәлекле, күңелләргә үтеп керә торган әсәр. Барлык китапларыгыз тормышчан, тәрбияви әһәмияткә ия. Иҗат чишмәләрегез гел тулып торсын! Рәхмәт!" | "Китабыгызны икешәр тапкыр укып чыктык. Сезнең иҗатыгыз белән Сургутта да, Төмәндә дә танышлар. Иҗатыгыз саекмасын!" | "Һәр китабыгызда хатын – кызның авыр язмышы тасвирлана. Шундый язмышлы кешеләр турында укыгач, минем күргәннәр чүп кенә дип уйлыйсың. Бирешмичә алга барырга көч бирә торган әсәрләрегез өчен зур рәхмәт!" | "Рәхмәт сезгә шундый тирән фәлсәфәле китапларыгыз өчен! Алар безгә яшәргә максат, көч, сабак бирә. Исән – сау булып, армыйча иҗат итегез." |

Тагын бер факт мине куандырды. Казанның үзәк китапханәсе системасы челтәре үткәргән "Иң күп укыла торган авторлар" исемлегендә Гөлсинә Галимуллина фамилиясе Зифа Кадыйровадан кала икенче урында тора.

Туган төбәгебездә тагын бер яңа каләм әһеле барлыкка килүгә мин шатланам һәм горурланам. Гөлсинә Галимуллина киләчәктә безне яңадан – яңа әсәрләре белән куандырыр дип, чын күңелдән ышанып калам.

Китап безнең рухыбызда, иманыбыз сагында яши, аңа күңел түре кирәк. Бөек Тукай юкка гына "Гомеремнең иң читен, җайсыз, уңайсыз бер минутында кулыма китап алам"- дип язмаган. Чөнки кулына китап алып укып, елый һәм көлә алганнарның күңелендә начарлык булмый.

*Кулланылган әдәбият:*

Галимуллина Г.Ефәк кулъяулык.- Казан: ТАТМЕДИА Идел - Пресс, 2014.-223б;

Галимуллина Г. Карлы миләш тәме.- Казан: ТАТМЕДИА Идел – Пресс, 2014.- 239б;

Галимуллина Г. Күгәрчен оя корганда.- Казан: ТАТМЕДИА Идел – Пресс, 2013. – 223б;

Галимуллина Г. Мәхәббәт аланы. – Казан: ТАТМЕДИА Идел – Пресс, 2012. – 85б;

Галимуллина Г. Ак бураннар аша. – Казан: ТАТМЕДИА Идел – Пресс, 2012. – 174б;

Галимуллина Г. Томанлы төн. Казан: ТАТМЕДИА Идел – Пресс, 2013. – 223б.

Д.Ф.Заһидуллина, Ә.М.Закирҗанов, Т.Ш.Гыйләҗев. Татар әдәбияты: Теория. Тарих. - Казан: Мәгариф, 2004.-255б;

Заһидуллина Д.Ф.Урта мәктәптә татар әдәбиятын укыту методикасы: Методик кулланма. - Казан: Мәгариф, 2000. - 335 б;

Исәнбәт Н.С. Татар теленең фразеологик сүзлеге. Ике томда.- Казан: Татар. кит.нәшр.,1990 – 365б;

Тәлгат Нәҗмиев Саба районы. Саба районы турында буклет.-Казан: Дом Печати,2007.- 34б;

Әдәбият белеме: Терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге. Казан: Мәгариф, 2007 .- 189б;

Әйтем – чәчәк, мәкаль – җиләк: Халык афоризмнары.- Казан: Мәгариф, 2002 – 191б;

"Шәһри Казан" – 19 февраль, 2015 ел – 5б.

## Г. ТУКАЙНЫҢ «ТУГАН ТЕЛ» ШИГЫРЕНЕҢ РУС, ИНГЛИЗ ТЕЛЛӘРЕНӘ ТӘРҖЕМӘ ИТҮ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

*Миннуллина Эльвина Маратовна*
*Казанский (Приволжский) Федеральный Университет, Казань, Россия*
*Фәнни җитәкче – фил.фәннәре канд, доцент Мухарлямова Л.Р.*

***Резюме***. *В данной статье рассматривается произведение Габдуллы тукая "Туган тел" в татарском, русском и английском языках. Здесь выявлены общие стороны произведений, а также отличия.*

**Ключевые слова:** *туган тел, нөсхә, строфа, рифма*

«И туган тел, и матур тел», - дип башланып китә халкыбызның, милләтебезнең, һәм әлбәттә, беренче чиратта, телебезнең югалмас гимны. Бөек Тукай бу әсәрен 1909 нчы елда иҗат иткән. Шушы шигырендә ул газиз татар теленә карата кичергән бар хисләрен,назлы мөнәсәбәтен белдерә. Бу шигырь бар дөньяга таралган дигән фикер дә хәзерге көндә ялгыш булмас.

Фәнни хезмәтемнең төп максаты: Габдулла Тукайның «Туган тел» шигыренең рус һәм инглиз телләренә тәрҗемәсенең үзенчәлекләрен ачыклау, аермалы якларын билгеләү.

Өч телдә дә хикәяләү беренче заттан бара. Шагыйрьнең укучы белән үз хис-кичерешләрен уртаклашуы аның тартым һәм зат алмашлыклары кулллануы аша тасвирлана: *«Дөньяда күп нәрсә белдем»* , *«Кечкенәдән аңлашылган шатлыгым, кайгым минем» , «я познавал» , «я сказки слышал» , «я не раз творца молил», «I learned with patience».*

Шигырь бербөтенлирик герой һәм «туган тел» арасында диалог рәвешендә бара. Әлбәттә, бу диалог берьяклы гына. Авторның «туган теленә» мөрәҗәгать итүен күпсанлы эндәш сүзләр, алмашлыклар дәлилли: *«И туган тел, и матур тел, әткәм-әнкәмнең теле!» ,*

*«И туган тел! Һәрвакытта ярдәмең белән синең», «ты моей навеки стал», «я и горе на тебе лишь выражал», «с тобою я не раз Творца молил»,«Oh, my language, native language, you are my soul and you are my heart…» «You are the treasure of my heart».*Туган тел бу очракта безнең күз алдыбызга чын, тереҗан иясе булып килеп баса.

Әсәр гади аңлаешлы телдә язылган, укучы тарафыннан бернинди кыенлыкларсыз кабул ителә. Тик шуңа карамастан, татар телендә ягъни төп нөсхәдә Габдулла Тукай архаизмнар куллана: *«кыйлган догам»,«Ярлыкагыл»,* ә рус һәм инглиз телендә әсәрнең бу үзенчәлекле ягы исәпкә алынмый. *«Ярлыкагыл»*сүзе рус теленә *«помилуй»,* ә инглиз теленә *«bless»* дип тәрҗемә ителә.

Өченче һәм дүртенче строфаларда Габдулла Тукай туган telenенең әһәмияте турында яза, аның кайгыда да, шатлыкта да таянычы, терәге булуын ассызлыклый. Әсәрнең дүртенче строфасында без Тукайның ачыктан-ачык Аллаһка мөрәҗәгать итүен, аның белән тыгыз бәйләнештә булуын күрәбез: *«Синдә булган иң элек кыйлган догам: Ярлыкагыл, дип, үзем һәм әткәм-әнкәмне, ходам!»*Тәрҗемә вариантларында да, әлбәттә, эчтәлек саклана.

Әсәр эмоциональ яктан бик бай, моны безгә һәр строфадан соң куелган өндәү билгеләре дәлилли. Әсәрдә зур урынны *«әткәм-әнкәмнең»* дигән кушма сүз алып тора, чөнки ул кешенең буыннан-буынга килгән нәсел тамырларын ассызлыклый. Инглиз телендә бу сүз *«native»*, ә рус телендә *«родительский»* сыйфатлары белән бирелә, һәмаларның төрле сүз төркемнәренә каравы аларның мәгънәләрен берничек тә үзгәртми, әдәби үзенчәлекләрен югалтмый.

*О язык родной, певучий, о родительская речь!*
*Что ещё на свете знал я, что сумел я уберечь?*
*И туган тел, и матур тел, әткәм-әнкәмнең теле!*
*Дөньядакүпнәрсәбелдемсинтуган тел аркылы.*
*Oh, beloved native language*
*Oh, enchanting mother tongue!*

Төп нөсхәдә сорау җөмләләр юк, ә рус тәрҗемәсендә бу күренеш беренче строфада ук күзәтелә:

*Что ещё на свете знал я, что сумел я уберечь?*

Шулай ук *«Һәрвакытта ярдәмең берлән синең»*дигән өзек тә рус теленә *«мы навечно неразлучные друзья»*, ә инглиз теленә *«You have been always my support»* дип тәрҗемә ителә. Ягъни инглиз тәрҗемәсе бу очракта Тукай нөсхәсенә якынырак дигән нәтиҗә ясап була.

Шигырь өч телдә дә дүрт строфадан тора, әмма рус һәм татар телләрендә строфада икешәр генә юл, ә инглиз телендә – дүрт:

*Oh, beloved native language,*
*Oh, enchanting mother tongue!*
*You enabled my search for knowledge*
*Of the world, since I was young.*

Әсәрне төзелеше ягыннан бәяләгәндә, өч телдә дә рифма, ритм саклануына инанабыз. Рифма татар һәм рус телләрендә ААББВВГГ, инглиз телендә исә АБАБ рәвешендә бирелә. Шуннан чыгып, татар һәм рус телләрендә әсәр 15/15 үлчәме белән язылган, ә инглиз теле тәрҗемәсендә 7/7 үлчәме күзәтелә.

Нәтиҗә ясап шуны әйтергә була: рус, инглиз тәрҗемәләрендә Габдулла Тукайның *«Туган тел»* әсәренең эчтәлеге искиткеч матур һәм, һичшиксез, дөрес бирелгән. Бер карашка, алар аерылмый сыман. Тик, шуңа да карамастан, аермалы яклар да шактый күп икән: биредә Тукай теленең үзенчәлекләре ягъни кулланылган архаизмнар, кайбер сүзтезмәләр, җөмләләр тәрҗемәсендә һәм хәтта әсәрләрнең төзелешендә дә аермалар табылды.

*Кулланылган әдәбият:*


1. Зинетуллина А.А. Фразеологические единицы с компонентами күңел/кăмăл в татарском и чувашском языках / Зинетуллина А.А., Мухарлямова Л.Р. // Материалы VIII международной научно-практической конференции «Актуальные вопросы

филологии и переводоведения: актуальные проблемы и тенденции развития в эпоху глобализации», посвященная 65-летию факультета иностранных языков чувашского государственного педагогического университета им. И. Я. Яковлева. – Чебоксары, 2016. – С. 228-232.
2. Габдулла Тукай: Стихи – Поэмы – Сказки. – Казань, 1990.

# К.КАРИМОВНЫҢ «КОМ СӘГАТЕ» ҺӘМ «САКАУ КҮКЕ» ӘСӘРЛӘРЕНДӘ ФОЛЬКЛОР ТРАДИЦИЯЛӘРЕ

*Николаева Юля Николай кызы, 9 нчы сыйныф укучысы*
*Фәнни җитәкче: Садыкова Лариса Павел кызы,*
*МБГБУ "Шәдче урта гомуми белем бирү мәктәбенең*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

Кеше тәрбияләүдә матур әдәбият әсәренең әһәмияте бик зур. Матур әдәбият – акыл үстерүнең, уй фикерне активлаштыру һәм төзекләндерүнең, тормышның гыйбрәтле мизгелләрен өйрәтүнең дә бик бай чыганагы. Әдәбият тормышны аңларга өйрәтә. Матур әдәбият әсәрләре кешенең рухи дөньясын баета, аларны бер – берсенә карата игътибарлы булырга, тирә - юньдәге вакыйгаларга тиешенчә бәя бирергә өйрәтә, чөнки матур әдәбият үзәгендә - кеше, аның эчке дөньясы, кешеләрнең үзара мөнәсәбәтләре, аларның дөньяга карашы. Бөтен дөньяны телевизор, интернет кебек мәгълүмат чаралары басып барган вакытта, яшьләрнең дөньяга карашын формалаштыруда, кызганычка каршы, әдәби әсәрләрнең роле кими. Шуңа да карамастан, көн кадагына суга торган, мавыктыргыч һәм тирән эчтәлекле романнарны бүгенге көндә дә яратып укучылар күпчелек дип уйлыйм.

Чорның үзенчәлекләрен төгәл күрсәтә һәм укучыны мавыктыргыч вакыйгалар эченә алып кереп китә ала торган романнар авторы – Камил Кәримов. Аның исеме татар әдәбияты белән кызыксынучыларның күбесенә таныш. Күп еллар «Казан утлары» журналында эшләве дә, юмор остасы, бүген исә халык яратып укыган, үз иткән романнар авторы булуы да аны бар татар дөньясына билгеле итте.

«Ком сәгате» дигән күләмле әсәренә язучы инде йөзгә якын хикәя язгач кына керешә. Яшьлек елларында үзе дә шактый еллар су бораулау мастеры булып эшләгәнлектән, темасы таныш. Язучының тәҗрибәле хикәя остасы булуы «Ком сәгате»ндә дә ярылып ята: кайбер бүлекләре хәтта мөстәкыйль хикәя рәвешен алган.

Тагын... «Сакау күке», «Игезәкләр йолдызлыгы», «Уен». Укучы хөкеменә ирешкән бу романнар соңгы ун елда язылган. Әйе, канатлы гыйбарәләр, саллы фикерләр, чагыштырулар, өр-яңа, кызыклы, шәп детальләр. Бүгенге тормышны сурәтләгән, үз геройларын реаль рәвештә, барлык уңай һәм кире яклары белән тасвирлаган Камил Кәримовның «Ком сәгате» һәм «Сакау күке» дилогиясе аерым игътибарга лаек.

Юкка гына түгел дилогия фән белгечләре, галимнәр – Яхин, Юсупов, Гыйльманов тарафыннан тикшерелә. Гәҗит-журналларда романга багышланган мәкаләләр дөнья күрә. 2012 елда Камил Кәримов «Ком сәгате» һәм «Сакау күке» романнары өчен Тукай премиясенә дәгъвә ителә. Ләкин К.Кәримов дилогиясенең фольклор белән бәйләнеше өйрәнелмәгән өлкәләрнең берсе. Бу мәсьәләне өйрәнү үткер, җор телле авторның әсәрләрендә киң кулланылган: канатлы сүзләр, мәкаль-әйтемнәр, элек-электән килгән гореф-гадәтләр, йолаларны һәрьяклап тикшерүне, җентекләп анализлауны таләп итә. Әсәрләренең бу яктан өйрәнелмәгән булуы фәнни эшемнең яңалыгын һәм **актуальлеген** билгели.

Хезмәтемнең **максаты** итеп Камил Кәримовның «Сакау күке» һәм «Ком сәгате» дилогиясенең фольклор белән бәйләнешен өйрәнүне алдым.

Максатыма ирешү юлында түбәндәге **бурычлар** куелды:

а) авторның иҗаты белән кыскача танышу;

ә) Камил Кәримовның «Сакау күке» һәм «Ком сәгате» дилогиясеннән халык авыз иҗатын эзләү;

б) дилогиядә булган фольклор материалларын табу, өйрәнү һәм анализлау.

Тикшерү **объекты** булып Камил Кәримовның «Сакау күке» һәм «Ком сәгате» әсәрләре тора.

Тикшерү **предметы** – «Сакау күке» һәм «Ком сәгате» әсәрләрендә фольклор.

Эш барышында кулланылган **методлар**: эзләнү, чыганаклар анализы, күзәтү, синтез.

Эшнең **структурасы** керештән, ике бүлектән ( I бүлек «Ком сәгате» һәм «Сакау күке» әсәрләрендә гореф - гадәтләр, йолалар, бәйрәмнәр; II бүлек Әсәрдә мәкаль - әйтемнәр, табышмаклар, канатлы сүзләр.) һәм файдаланылган әдәбият исемлегеннән тора. Кушымтада Камил Кәримов турында белешмә бирелде.

**Гореф – гадәтләр, йолалар, бәйрәмнәр**

Фатих Урманченың “Борынгы миф һәм бүгенге шигырь” дигән китабында халык иҗатына кызыклы караш бар. “Поэзиянең барлык уңай сыйфатлары, барлык атрибутлары барыннан да элек халык иҗатында формалаша. Борынгы шәрык үрнәкләре - ташка күчерелгән мифологик хикәятләр, төрле изге йолалар һәм тантаналы вакыйгалар белән бәйләнгән ритуаль гимннар, мәкаль - әйтемнәр, дастани-эпик формулалар... Һәм, ниһаять, бихисап дини догалар. Шулай булгач, халык иҗаты белән турыдан-туры бәйләнеш чыннан да язма поэзиянең тәүге, иң борынгы һәм безнең көннәргә кадәр уңышлы дәвам итеп килгән бердәнбер һәм тотрыклы сыйфаты”.[18]

Фольклор халыкның электән чыгарылып килгән традицион һәм хәзерге авыз-тел иҗатын иңләп ала, димәк, чәчмә әсәрләр дә, шулай ук шигъри текстларны да үз эченә берләштерә.

Барыннан да элек, фольклор телдән иҗат ителүе һәм телдән – телгә күчеп яшәве белән аерылып тора. Икенче төрле әйткәндә, халык авыз иҗаты ул сүз – тел сәнгате, телдән чыгарыла һәм телдән сөйләнә, ләкин телдән башкарыла торган иҗат. Бу гасырлар тирәнлегеннән килә торган сыйфат.

Камил Кәримовның «Ком сәгате» һәм «Сакау күке» дилогиясендә фольклор традицияләре мул һәм уңышлы кулланыла. Күп вакыт мәкаль - әйтемнәр, канатлы сүзләр җор, бай телле төп герой – Фазыл тарафыннан әйтелә. Бу аның балачак хатирәләренә, авылда үткәргән көннәренә, «Ак чишмә» оешмасында бригада эчендә бер-берсе белән аралашу вакытына үрелеп бирелә.

«Ком сәгате» әсәрендә яз көнендә иң башлап үткәрелгән элекке иң олы йола – бәйрәм – *Нәүрүз* дә искә алынып китә. Бу да бит татар халкының фольклорына керә, чөнки фарсылар календаре йогынтысында барлыкка килгән һәм, Нардуган бәйрәме кебек үк, яңа елны һәм өлешчә язны каршылау йоласы булып исәпләнгән.

Нәүрүз көннәрендә (ул берәр атнага — 10 көнгә сузылган) йорттан-йортка кереп «нәүрүз әйтеп» йөрү гадәте булган. Моны укучы балалар, шәкертләр башкарган. Нәүрүз такмагын укып, яки яттан әйтеп, хуҗаларга бәхет, уңышлар теләп йөргәннәр.

Уен — күңелгә куаныч, юаныч бирә торган шөгыль. Уен буш вакытны үткәрү, эчке борчуларны, кайгыны бетерү һәм бер өлкәдә сәләтне үстерү өчен үткәрелә.

Уеннардан, аерым алганда, автор кардан окоп казып «*ядрә атышу»*, җәй житүгә тыкрыктагы юл тузанын кепкаларга тутырып *«бомба ыргыту», «әүмәкләшү»* уеннары турында әйтеп үтә.

Һәр милләт үз җирлегендә барлыкка килгән һәм буыннан-буынга күчә торган гореф-гадәтләрен, кешеләрнең яшәү рәвешләрен, үз-үзләрен тоту кагыйдәләрен, карашларын, зәвыкларын сакларга омтылган.

---

[18] Ф.Урманче. Борынгы миф һәм бүгенге шигырь./ Ф. Урманче. - Казан: Школа нәшр., 2002. - 10 б.

Тормыш–көнкүрештә билгеле бер йолалар үтәү, гореф-гадәтләрне тоту һәм бәйрәмнәр үткәрү барлык милләтләргә дә хас. Ул әлеге милләт мәдәниятенең мөһим бер өлеше булып исәпләнә. Гореф-гадәтләр борын-борыннан халык тарафыннан үтәлеп килә торган бәйрәмнәрне, йолаларны үз эченә ала. Билгеле бер йолаларның үтәлеп килүе җәмгыятьне дә тотрыклы итә, алардан башка халык тулы кыйммәтле тормыш белән яши алмый.

Татар халкының гаилә йолалары арасыннан үзенчәлекле бер йоласы бар. Бу бала туу белән бәйле булган ир баланы сөннәткә утырту йоласы. Элек – электән ир балалары булган гаиләләр сөннәт йоласын үтиләр, чөнки бу ата-ананың изге бурычы.

Халыкның яшәү үзенчәлекләре, йола - ритуалларын - сөннәт темасын да ачыклап китә Камил Кәримов:

*«...Лаеш ягыннан биштәрле бабай килә дә малайларның уенын берәр атнага туктатып тора.*

*Бабай килер алдыннан өйдәгеләрнең телендә гел сөннәтне мактау: «Зур егет инде син, су коенганда «урыс малае» дип көлмәсеннәр, менәтерәк чистарып каласың...”Өлкәннәр сүзенә иләнеп, үзең дә Бабайны көтеп йөрисең, сина үсәргә комачаулаган нәрсәдән тизрәк котыласың килә.*

*Бабайның исемлеге бар, кемнең ничә яшьлек малай үстергәнен алдан ук белеп тора, шуңа күрә аны эзләп, яисә иартеп кайтасы юк, ул үзе килеп керә. Иске чалбарыңны салып урын өстенә ятарга куша. Яңасын тегеп алып килəм дип үлчәм алырга тотына. Яңа чалбар кигәндә комачаулыйсы әйбереңне үртәштергән арада «чебен» тешләп ала. Еларга ярамый, юкса бабай син елакны башка малайларга сөйли».*[19]

Мөселман дине буенча, туган көнне исәпкә алмыйча, җиденче көндә сөннәткә утырту – Аллаһ илчесенең күрсәтмәсе.

Мөселманнарга ир баланы туганнан соң нәкъ менә җиденче көндә сөннәтләү мөһим. Хәдистә болай диелә: «Пәйгамбәребез Мөхәммәт оныклары Хәсән һәм Хөсәенне туганнан соң җиденче көндә сөннәткә утыртты» (Раваху Табарани). Димәк, балигъ булу белән сөннәтле булу мөселман кешесенең бурычына әйләнә.

Үзенчәлекле, татар халкына гына хас «тәмле сүз» белән күрсәтеп бирә Камил Кәримов сөннәт күренешен. Чынлап та, сөннәтләү - татарларда элек – электән килгән иң зур бәйрәмнәрнең берсе булган.

Ырымнар – халык иҗатының магия, ягъни сүз һәм хәрәкәт – йола кодрәтенә ышану белән бәйләнешле борынгы жанры, хыялый көчләргә һәм ияләргә тәэсир итеп ниндидер нәтиҗәгә ирешү өчен чыгарылган һәм шул максатта кулланылган тылсымлы сүз формулалары яки калыплашкан магик гайбарәләр.[20]

«Сакау күке» әсәрендә дә Язилә үзенчә ырым эшли:

*Язилә көне буе суытмыйча саклаган чиләкле суны түгәрәк калай ләгәнгә бушатып, Фазылны шунда бастырыр, аның аякларын юар. Үзе юар, үзенең сул кулы ирнең челтереннән кысып торыр, уң кулының балдак киярга хаклы бармагы тыңгысыз ирнең табан астын кытыклар, үзе бәет сөйләгәндәй такмаклар:*

*Тагын шунда бер барганыңны сизсәм –*
*Ул кызны эзләп табармын,*
*Бөтен мәктәп алдында рисвай итәрмен,*
*Хатынлы ирләрне азындырмасын.*
*Син минем чәчәгемне койдың,*
*Ир бирмәк – җан бирмәк...*[21]

Романның башында, Фазыл авыр чирдән котыла алмаячагын һәм бары тик утыз көнләп яшәячәге калганын белгәч, чегән хатыны аңа әйткән юрамышны исенә төшерә:

---

[19] Кәримов К. Сакау куке: Роман, повесть. – Казан: Тат. китап нәшр. 2005 – 37 б.

[20] Ф.Урманче. Борынгы миф һәм бүгенге шигырь. / Ф. Урманче. - Казан: Школа нәшр., 2002. – 22б.

[21] Кәримов К. Сакау куке: Роман, повесть. – Казан: Тат. китап нәшр. 2005. – 65б.

*«Үскәч, акча күп эшләрсең, ну бай булалмассың. Сиңа дигән хатын тагын ун елдан соң туачак. Улыңны кеше үстерер, кызың үз кулыңда үсәр. Туксан алты яшькәчә яшәрсең...»*

Юрамыш – шулай ук, фольклор традицияләрен үз эченә алган күренеш. Теге яисә бу мәгълүматны алдан әйтеп бирү, алдагы тормышыңны юрау, күрәзәчелек элек – электән авылларда билгеле булган.[22]

Афористик жанрларның халык арасында шактый киң таралганы - ышанулар:

«*Балалар су кererгә киткәннәр, күке кычкырдымы соң әле»,* монысы инде икенче төрлесе:

*Күке кычкыргач кына су керергә ярый.*

*Кич чишмәгә суга төшәргә ярамый.*

*Ут сызгырса, еракtан хәбәр килә.*

*Бал белән авызланганның теле татлы булыр, май белән авызланганның теле йомшак булыр.*[23]

*Бусагага утырсаң, ярлы буласың, диләр*[24]

Ышануларның төп максаты – киләчәктә безне ни көтәсен алдан әйтеп, юрап кую.

Шулай итеп, гореф – гадәтләр, йолалар, бәйрәмнәр Камил Кәримовның «Ком сәгате», «Сакау күке» романнарында тулы кимәлендә кулланылган. Халык авыз иҗаты белән якыннан таныш булган автор, татар халкы өчен мөһим булган – Нәүрүз бәйрәменең; сөннәтләүнең асылларын ача. Бу бәйрәмнәрнең гади кеше тормышында зур роль үтәгәнен күрсәтә.

Болардан башка, әсәрләрдә юрамышлар, ышанулар, ырымнар бик урынлы һәм уңышлы кулланылганнар. Алар төп геройның яшәү рәвешен, идеалларын, максатларын ачарга ярдәм итә.

Күргәнебезчә, халкыбызның йола, гореф-гадәт һәм бәйрәмнәрен өйрәнү зур әһәмияткә ия. Дөрестән дә, диннән, телдән башка яши алмаган кебек, халык алардан башка да милләт буларак яшәвеннән туктар иде. Татар халкы һәр вакыт үзенең йолаларына тугры булды. Чөнки алар безгә бик ерак бабаларыбыздан мирас булып калганнар. Тик онытмаска, сакларга , буыннан буынга җиткерергә иде аларны. Татар халкының борынгыдан килгән ел фасылларына бәйле Сабан туйлары, Нәүрүз, Питрау, Нардуган, Сөмбелә; ислам диненә бәйле Рамазан һәм Корбан бәйрәмнәре; йолаларга бәйле каз өмәсе, исем кую, туй мәҗлесләрен уздыру, кеше күмү, сөннәткә утырту; аулак өйләр, утырмалар бүгенге көндә дә сакланган.

Адәм баласы әти-әнисен, кендек каны тамган туган җирен, ана телен, динен, гореф-гадәтләрен, йолаларын ихтирам итәргә тиеш. Табигый, буыннан буынга күчә торган рухи тәҗрибә һәм йолалар вакытлар узу белән һич тә әһәмиятләрен югалтмыйлар, киресенчә, аларның кыйммәте арта гына. Моның шулай булуы әдәби әсәрләр мисалында тагын бер кат исбатлана.

Татар халкының бу күңел җәүһәрләре әдәби әсәрләр аша киләчәккә тапшырыла, чөнки ул китап булып, милли мирасыбыз булып буыннар арасындагы бәйләнешне тәэмин итеп тора. Әдәби әсәрләр кешенең иҗадилыгын, фикерләү сәләтен, аң һәм интеллектын үстерә. Аңа тормыш тәҗрибәсе тупларга, матурлыкны күрергә һәм әхлакка өйрәнүгә омтылыш тәрбияләүче чара да булып торалар.

**Мәкаль - әйтемнәр, табышмаклар, канатлы сүзләр**

Камил Кәримовның «Ком сәгате», Сакау күке» дилогиясендә гореф – гадәт, йолалардан башка мәкаль - әйтемнәр, канатлы сүзләр үз урынын алган. Юмор өлкәсендә эшләп килгән автор, дөрес һәм табышлы итеп мәзәкләрне дә кулланырга онытмаган.

Канатлы сүзләр турында аерым әйтеп үтәргә кирәк, авторның телләрендә алар шулкадәрле дә күп, хәтта ки аларны җыеп, аерым эш башкарып була.

---

[22] Ф.Урманче. Борынгы миф һәм бүгенге шигырь. / Ф. Урманче. - Казан: Школа нәшр., 2002. – 23б.

[23] Кәримов К. Сакау куке: Роман, повесть. – Казан: Тат. китап нәшр. 2005. – 89б.

[24] Кәримов К. Ком сәгате / Кәримов К.// Казан утлары – 1999- №8,9.

Кеше кушаматлары, җир – су атамаларына килгәндә алар шулай ук мул кулланылган. Бу үз чиратында, уйдырма геройларны яшәгән төбәккә бәйләп, реаль рәвештә күрсәтә.

Дилогиядә аерым – аерым кулланылган жанр төрләрен карап үтик:

Мәкаль - сөйләшкәндә сүзгә ямь һәм куәт бирү өчен, көнкүрештә күп сыналган дәлил яки шигъри бер мисал урынында әйтеп йөртелә торган, кыска, ләкин гомуми бер, тирән мәгънәне эченә алган төгәл җөмләле халык хикмәте әсәре.

Әсәрдә кулланылган мәкальләр:

*«Ташка кадак какканнар»*- дип атала аның романынын бер өлеше.

*«Бала өчен яшәү- үзең өчен яшәү».*[25]

*«Эш узгач, уйнарга ярый»*[26] – дип кисәтә туй кичәсендә Фазылны бригада башлыгы, Язиләнең этисе - Әмир.

*«Чебешне көз көне санайлар».*

*«Уеннан уймак чыга».*

Табышмак – ул предметны читләтеп, кинаяле итеп сурәтләүгә корылган һәм тыңлаучылардан шуның нәрсә булуын эзләргә исәп ителгән образлы гыйбарә яки үзенчәлекле башваткыч.[27]

<u>*Табышмак:*</u> *«Ике аяклы, ике куллы – ләүкәдә утыра»(бака).*

Әсәрдә *әйтемнәр дә* урынлы һәм уңышлы кулланылалар.

Мәсәлән: Актаныштагы Аккүз авылында калган Әлфинәне Фазыл утыз ел буе сөйгән. Алар кавышмаганнар.

*«Ул кызны күргән кеше утыз елны күпсенмәс»,* - дип әйтеп куя төп герой.

*«Татар халкы ашамыйча кырык көн түзә ала, су эчмәсә - җиде көннән үлә, ә эшсез бер генә көн дә түзалмый.»*

Романнар язуга килгәнче, юмор өлкәсендә эш иткән Камил Кәримов, «Ком сәгате» һәм «Сакау күке» романнарында, аеруча уңышлы, канатлы сүзләрне куллана. Алар бихисап, ләкин мисал итеп түбәндәгеләрне китерергә мөмкин:

<u>*Канатлы сүзләр:*</u>

*Ир бала егет булып аягына басканчы, җүнле сыер унҗиде бозау үстерә.*

*Кеше табигатьнең иң иркә җан иясе.*

*Кул биреп күрешәләр икән, димәк, син инде егет кеше!*

*Көндезге тәүбә төн уртасы өчен әйтелми.*

*Ялганга өйрәнер өчен кешеләр арасында яшәргә кирәк.*

*Рәхәт булган җирдә хәтәр бар.*

*Хатын-кыз бәхете – ана булуда, ир бәхете – мәхәббәттә.*

*«Яратмаган кешең белән яшәү – ялгыз яшәүнең бер төре ул»*[28]

*«Э син «ах - ух» киләсең, үкенүдән бүселеп – кулыңдагы песнәкне күрмисең»*[29]

Шулай ук, әсәрдә җир – су атамалары, кушаматлар телгә алына.

<u>*Кушаматлар:*</u>

*Низам* (өч кешелек гаиләдә берүзе яши, ике кешелек ашый, өч кешелек эшли) - *өсте-өстенә кигән кепка, кечкенә буйлы абыйсыннан калган кәчтүн, каеш урынына чалбар билдәмәсенә уралган бичәүкә, түбә буявы белән тигезләп капланган кызгылт ботинкада*[30]

Тора – бара исем (бу очракта, чын – реаль кешенең исеме) кушаматка әйләнеп китә. Акылга җиңел булган, өс – кыяфәте белән башкалардан нык аерылып торган кешегә *Низам* диләр.

*Сигәк Хәсән, Сакал Шәйхи*

<u>*Атамалар:*</u>

---

[25] Кәримов К. Ком сәгате / Кәримов К.// Казан утлары – 1999- №8,9.
[26] Кәримов К. Сакау куке: Роман, повесть. – Казан: Тат. китап нәшр. 2005. – 74б.
[27] Ф.Урманче. Борынгы миф һәм бүгенге шигырь. / Ф. Урманче. - Казан: Школа нәшр., 2002. – 25б.
[28] Кәримов К. Сакау куке: Роман, повесть. – Казан: Тат. китап нәшр. 2005. – 91б.
[29] Кәримов К. Ком сәгате / Кәримов К.// Казан утлары – 1999- №8,9.
[30] Кәримов К. Сакау куке: Роман, повесть. – Казан: Тат. китап нәшр. 2005. – 44б.

*Каенлык очы* кызлары, *Пожарный буасы, Татцик һәм Шәле, Зират тавы, Пәрәү болыны, Үмәни күле*

Балачагын искә алганда, Фазылның күзалдына еш кына авыл урамнары, анда уйнап йөргән авыл малайлары килеп баса. Уен вакытында, монда такмаклар, җырлар ишетелә: *Казбек, Марсель һәм Митәйнең эти-әнисе таралып беткән урыс авылларыннан күчеп килгән. Татар балалары исемнәренә күрә, "керәшен" кушаматы тагып, җыр чыгардылар узләренә:*

*Керәшен, керәшен,*
*Ник чиркәүгә керәсең?*
*Анданиләр күрәсең -*
*Чыккач безгә сөйләрсең...*
*Җыр җавапсыз калмый:*
*Татар – үзенекенә батар,*
*Чыгалмыйча тик ятар!..*[31]

Такмаклар – бу бер төр җырлар халык җыр лирикасының аерым бер жанрын тәшкил итәләр һәм лирико – драматик әсәрләр буларак характерланалар. Мондый җырларда төрле ясыллыкта һәм төрле формада гәүдәләнә. [32]

Мәзәк – борынгы заманнарда ук туып, безнең көннәрдә дә актив яши һәм үсә торган жанр. Аның төп идея-эстетик кыйммәте тормыштагы төрле тискәре күренешләрне сатира-юмор ярдәмендә фаш кылуы, әдәп-әхлак нормаларын ныгытуга, кешеләрдә, бигрәк тә яшь буында югары рухи сыйфатлар тәрбияләүгә ярдәм итүе белән билгеләнә.[33]

Романда түбәндәге мәзәк бар:

*Малайны чүлмәк ватканчы кыйнарга кирәк, дигән Хуҗа Насретдин, ваткач соң була.*

Шулай итеп, Камил Кәримов тарафыннан "Ком сәгате" һәм "Сакау күке" дилогиясендә мәкаль - әйтемнәр, канатлы сүзләр мул кулланылган.

Һәр халыкның мәкаль-әйтеме үзенчә. Менә шулардай мәкальнең иң зур күпчелеге һәр халыкның үз иҗтимагый-тарихи тормыш тәҗрибәләреннән һәм ышануларыннан, аның үз теленең иҗат һәм сурәтләмә мөмкинлекләренә таянып барлыкка килгәнлеге аңлашыла. Аның кайчан туа башлаганы билгесез, авторлары исемсез, шулай ук аның әле дә туудан туктаганы юк. Тормыш һәм халык яшәгән җирдә аның тумавы мөмкин дә түгел: чөнки кеше үз табигате буенча шагыйрь, үзе тәҗрибә һәм иҗат иясе. Шунлыктан мәкаль башлап ялгыз кеше авызыннан әйтелсә дә, һәр уңышлы иҗатны эләктереп алучы халык аны телендә саклый, тагын да шомарта, чөнки аны гомуми мәгънәгә күтәрүче халык үзе бөек шагыйрь, үзе тормышны иҗат итүче бөек даһи ул.

Безнең тормышыбыз, яшәү рәвешебез ком сәгате кебек икән бит. Вакыт агышы ике якны әйләндереп карасаң да бер төрле, ә менә колбадагы комның төрле яссылыклар, иңкүлекләр ясап икенче бүрәнкәгә тулуы гына үзгә.

Кешенең тормышы да нәкъ шулай. Югыйсә барыбыз да бер вакыт аралагында, бер заманда гомер кичерәбез кебек. Ләкин яшәү рәвешләребез төрле-төрле: бәхетлеләр-бәхетсезләр, уңганнар-ялкаулар, ихласлылар-икейөзлеләр, хәерчеләр-байлар, тигезләр-тигезсезләр, парлылар-ялгызлар...

Хезмәтемнең **максаты** итеп Камил Кәримовның «Сакау күке» һәм «Ком сәгате» дилогиясенең фольклор белән бәйләнешен өйрәнүне алдым. Бу максатка ирешү өчен түбәндәге бурычлар куелды:

а) авторның иҗаты белән кыскача танышу;

ә) Камил Кәримовның «Сакау күке» һәм «Ком сәгате» дилогиясеннән халык авыз иҗатын эзләү;

б) дилогиядә булган фольклор материалларын табу, өйрәнү һәм анализлау.

---

[31] Кәримов К. Сакау куке: Роман, повесть. – Казан: Тат. китап нәшр. 2005. – 31б.
[32] Ф.Урманче. Борынгы миф һәм бүгенге шигырь. / Ф. Урманче. - Казан: Школа нәшр., 2002.
[33] Ф.Урманче. Борынгы миф һәм бүгенге шигырь. / Ф. Урманче. - Казан: Школа нәшр., 2002.

Шулай итеп, түбәндәге **нәтиҗәләргә** килдем: халык бәйрәмнәре, йола, гореф-гадәтләр язучыларыбызның күбрәк авылга багышланган әсәрләрендә сурәтләнә, чөнки авыл халыкның бик борынгыдан килә торган мондый хәзинәләрен үзендә саклаучы дөнья итеп карала.

Бүгенге каләм ияләреннән бу сафка Камил Кәримовны кертеп була.

Бер җепкә тезелгән вакыйгаларның һәммәсе дә тормыштан алынган. Тормышка якынрак булган саен, әдәби әсәрнең тәэсире дә көчлерәк була. Әдәбиятта халык авыз иҗатын куллану кителмәгән югарылыкларга ирешергә ярдәм итә, геройларның эчке халәтен, яшәү рәвешен, идеалларын тоярга булыша.

Камил Кәримов "Ком сәгате" һәм "Сакау күке" дилогиясендә халык авыз иҗатын мулдан куллана. Әсәрләрдә татар халкының элек – электән килгән гореф – гадәтләре, йолалары урын алган. Авторның бай, җор телен мәкаль - әйтемнәр, канатлы сүзләр аша күреп була.

Юрамышлар, ышанулар, ырымнар халыкның аерым бер көчләргә ышануын, күрәзәчелек мөмкинчелекләрен ачып бирә. Ә җир – су атамалары, кеше кушаматлары аерым бер төбәкнең үзенә генә хас колоритмын тоярга ярдәм итә.

Соңгы елларда халкыбызның туган җиренә, туган теленә, үткәненә, мәдәниятенә игътибары артканнан-арта бара. Бу үзгәреш йола, гореф-гадәт һәм бәйрәмнәрне үткәрүгә, онытылганнарын торгызуга һәм яңартуга китерә.

Буыннан-буынга күчеп килгән, бу рухи байлыкларыбыз бүгенге көннәрдә дә безнең тормышыбызның, яшәешебезнең бизәге булып тора.

Татар халкының борынгыдан килгән йола, гореф-гадәт һәм бәйрәмнәрен чагылдырган әдәби әсәрләр аша халкымның күңел җәүһәрләрен барлыйбыз, үткәнен киләчәк буыннарга җиткерәбез, киләчәккә ышанычын арттырабыз, милләтебезне саклауда бер юнәлеш булуын азсызыклыйбыз. Чөнки әдәбият аша гына халыкның бик тирәндә яткан сыйфат-хасиятләрен, үзенчәлеген, милли рухын тоеп, сиземләп була.

*Кулланылган әдәбият:*


1. Бакиров М.Х. Татар фольклоры: Югары уку йортлары өчен дәреслек. – Казан: Мәгариф, 2008. – 359 б.
2. Вәлиев М. Матбугат йорты – гомер китабы: Истәлек – хатирәләр. – Казан: Мәгариф, 2006. – 271б.
3. Даутов Р.Н. Балачак әдипләре: Библиографик белешмәлек. Икенче китап. – Казан: Мәгариф, 2004. – 289б
4. Кәримов К. Ком сәгате. Казан утлары. – 1999 - № 8,9.
5. Кәримов К. Ком сәгате. Казан утлары. – 2003 - № 7,8,9.
6. Кәримов К. Ком сәгате. Казан утлары – 2010 - № 4,5.
7. Кәримов К. Сакау күке: Роман, повесть. – Казан: Тат. китап нәшр. 2005 – 303 б.
8. Татар календаре. Казан: Мәгариф нәшрияты, 2010.
9. Урманче Ф.И. Борынгы миф һәм бүгенге шигырь. - Казан: Школа нәшр., 2002. - 10б.
10. Яхин Ф. Ком сәгате романы чыгу уңаеннан. Мәйдан – 2010 ел - № 6.

# РИФӘ РАХМАННЫҢ “ЮГАЛТУ АЧЫСЫ” КЫЙССАСЫНДА ГЕРОЙЛАР ҺӘМ ПРОТОТИПЛАР

*Сәфаргалиева Зилә Нәсих кызы, 9 нчы сыйныф укучысы*
*Фәнни җитәкче: Шәмсетдинова Сания Вагыйз кызы,*
*Сәрдекбаш урта мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

Һәркем үзенең нәсел җебен, әби-бабасын белгән кебек, үз төбәген, аның тарихын, күренекле кешеләрен белергә тиеш. Моны белгән кеше генә горур була. Ә горур кеше – абруйлы кеше. Безнең төбәктә туып-үскән иҗат әһелләре арасында әсәрләре һәркемнең өстәл китабы булырлык танылган каләм ияләре бар. Әдәбият дәресләрендә без аларның иҗатын теләп, яратып өйрәнәбез. Рифә Рахман әсәрләре безгә аеруча якын. Аның шигырьләре ихласлыгы, тормышчанлыгы, һәркемгә аңлаешлы булуы белән аерылып тора. “Шигырьләрен укый башлыйсың, синең хакта, танышларың хакында язадыр, һәркемнең җанын ачып укыйдыр шикелле”,- дип яза аның турында З.Җиһаншина “Якташым турында берничә сүз” мәкаләсендә [5, 77]. Әсәрләренең безнең тарафтан аерым бер кызыксыну белән кабул ителүенең сәбәбе, бәлки, шуның белән аңлатыладыр да. Шигырьләреннән туган як табигатенең таныш урыннарын күрү, таныш исемнәр ишетү, аның поэзиясен күңелгә якын итә. “Мәмәширдә”, “Ничек хәлләрегез”, “Мин туганчы” кебек шигырьләре нәкъ шундыйлардан. Ә бүгенге безнең **эзләнү эшенең темасы:** Рифә Рахманның “Югалту ачысы” кыйссасында геройлар һәм прототиплар.

**Эзләнү эшенең максаты:** Р.Рахман әсәренең чынбарлык белән бәйләнешен, прототипларын һәм аларның әдәби образларда чагылуын ачыклау.

Максаттан чыгып, түбәндәге **бурычларны** билгеләдек:

1) Р.Рахман иҗаты турындагы мәкаләләр белән танышу;

2) Сәрдек-Баш авылы тарихы, мәгариф тарихы турында мәктәп музее материалларын өйрәнү;

3) әсәрдәге образларны прототиплары белән чагыштырып анализлау.

**Тикшеренү эшенең гипотезасы (фаразы):** Р.Рахман әсәренең прототиплары безнең Сәрдек-Баш авылында яшәгән. Әсәр реаль вакыйгаларга нигезләнеп язылган.

**Эзләнү эшенең объекты:** Р.Рахманның “Югалту ачысы кыйссасы.

**Эзләнү эшенең предметы:** кыйссада сурәтләнгән вакыйгалар, геройларның прототиплары.

**Эзләнү эшенең методлары:**

1) чагыштыру;
2) биографик;
3) аналитик;
4) сорашу, әңгәмә.

Эшнең **актуальлеге** шунда: Р.Рахманның бу хикәясе әле әдәби тәнкыйтьтә аерым анализланмаган, геройлар һәм прототиплар чагыштырып тикшерелмәгән. Бу эшне әдәбият дәресләрендә якташ әдипләр иҗатын өйрәнгәндә өстәмә материал итеп файдаланырга мөмкин булачак.

**Әсәрнең жанры**

Рифә Рахман “Югалту ачысы” кыйссасын 2004 нче елда яза. Әсәрнең реаль вакыйгаларга нигезләнүенә ишарәләп, “Мине карап үстергән кадерле әбиемнең якты рухына багышлыйм”, - дип язган. Әдәбиятта кыйсса жанры үзе үк чынбарлыкка, реаль вакыйгаларга дәгъва итә. Бу жанрга әдәбият белеме сүзлегендә мондый билгеләмә бирелә: “Кыйсса (гарәпчәдән — хикәя, тарихи вакыйга, риваять) — мөселман Шәрык халыклары фольклоры һәм әдәбиятындагы дастанга якын булган эпик, кайвакыт лироэпик жанр. Гарәп, фарсы һәм төрки телләрдә «кыйсса» атамасы белән хикәят, повесть, әкият, риваять һ.б. жанрларны атыйлар.Кыйссада, гадәттә, нинди дә булса гадәттән тыш, кызыклы, мавыктыргыч, драматик, гыйбрәтле вакыйгалар, хәлләр хикәяләнә, бәян ителә. Сюжет үстерелеше кайвакыт лирик

кичерешләр, төрле уйланулар белән кушып бирелә. Кыйссада конфликт кискенлеге кайвакытта трагик характерда булуы белән аерылып тора" [1, 83].

**Әсәрдәге образлар**

Иң беренче итеп образ төшенчәсенә тукталып китик. Аның "Әдәбият белеме сүзлеге"ндәге билгеләмәсе түбәндәгечә:

"Образ-... әдәби иҗатның табигатен, формасын һәм вазифасын билгели торган төп төшенчә. Образның үзәгендә кеше тормышының конкрет һәм
шул ук вакытта гомумиләштерелгән, иҗади уйланма ярдәмендә тудырылган һәм эстетик әһәмияткә ия булган сурәтләнеше тора" [1, 125]

"Әтисе кайтып кергәндә, Шәмсенаһар сәке кырыена бүкән куеп баскан да тырыша-тырыша камыр изә иде. Озын итеп тегелгән күлмәгенең итәкләрен, җыеп, ыштан бөрмәсенә тыккан, яулыгын артка чөеп бәйләгән. Нәкъ мәрхүмә әнисе инде менә, дип уйлады, аңа карап, Габидулла, нәкъ әнисе..." [6, 134]. Әсәрнең башыннан ук автор укучыны төп герой белән таныштыра. Башка геройларның характеры төп герой белән бәйләнештә, аның күзлегеннән чыгып бәяләнә. Шулай итеп, кыйссада Шәмсенаһарның алты яшьлек бала чагыннан алып, үлгәнчегә кадәрге бөтен тормышы яктыртыла.Ниләр генә кичми аның башыннан? Кадерле әнисен, яраткан абыйсын, соңрак әтисен югалту ачысы да, ачлык-ялангачлык газаплары да, тамак ялына бөтенләй чит кешеләргә хезмәт итү дә, инде тормышка чыгып, үз гаиләсен булдыргач, бәхеткә тиендем, дигәндә генә ирен Бөек Ватан сугышына озатып, аның үлем хәбәрен алу да, иренең туганнары тарафыннан кагылу-сугылулар да – барысын да кичерә Шәмсенаһар. Укып чыккач, гаҗәпләнеп куясың: бер кеше өчен исәпсез күп түгелме соң бу хәсрәтләр? Бу авырлыклар алдында сынмаска, сыгылмаска, исән калырга каян, нинди көчләр таба ул?

Шәмсенаһар кечкенәдән бик тырыш, эшчән кыз була. Алты яшеннән ипи пешерә, сыер сава белгән кыз бер эштән дә курыкмый. Күрше мари авылына барып, бәби дә карый, урак та ура, үзеннән өч яшькә кечерәк энесе Гарифны да карап үстереп, мөстәкыйль тормышка озата. Карусыз кызның һәр көне, сәгате хезмәттә үтә. Шуның өстенә ятимлек, кешеләргә кирәк булмау, кимсетүләр изә аны. Шулай булуга карамастан, Шәмсенаһар киң күңелле, сабыр холыклы, мәрхәмәтле булып кала белә. Кырыс тормыш сынауларын кичергән карчыкның күңеле тупасланмый, ул җан җылысын якыннарына да, бөтенләй чит кешеләргә дә кызганмый. Бөтен татар хатыннарына, татар әбиләренә хас сыйфаты аның – сабырлык. Бу яктан ул күпмедер дәрәҗәдә Ә.Еникинең ак күңелле Акъәби образына охшап китә.

Әсәрдәге башка образлар төп рольне уйнамыйлар, ләкин алар Шәмсенаһар образын тулырак ачарга ярдәм итәләр. Габидуллага яшь хатын булып килгән мулла кызы Хатимә образы шундыйлардан. Без экиятләрдән укып белгән явыз үги ана да түгел ул үзе. Шул ук вакытта ятимнәрнең тормышын җиңеләйтү, боеккан күңелләрен юату өчен берни дә эшләми. Ирен Гражданнар сугышына алуга, "ятимнәр белән торуны авырсынып, әтисе йортына күченә". Аның белән бергә яшәгән чорда барлык авыр эшләрне үзе башкарган Шәмсенаһарның түземлеге,сабырлыгы, карусызлыгы сокландыра.

Шәмсенаһар язмышында зур роль уйнаган тагын бер герой - укытучы Файзрахман. Үзләрендә фатирда торган үтә дә миһербанлы бу егетне Шәмсенаһар баштан ук үз итә, улы Хаммат белән тигез күреп ярата. Тормышының иң авыр вакытында, кайнанасы, каенсеңелләре тарафыннан кагылып-сугылып көн иткәндә, Файзрахман да аңа терәк була: Шәмсенаһарны авылына алып китә, әнкәсе урынына күреп, түрен бирә, үзенә сыендыра. Бу чор, мөгаен, аның тормышының иң матур, иң бәхетле еллары булгандыр. Бу гаиләдә ул үзен кеше итеп хис итә. Үзенең кирәклеген тою, Файзрахман балаларының яратуы, авыл кешеләренең яхшы мөнәсәбәте аны бәхетле итә. Ул бөтен назын, күңел җылысын биреп, Марат белән Зиләне үстерешә. Әлеге гаиләнең ак әбисе булып яши. Ләкин мондагы тормышы ничек кенә рәхәт булмасын, туган авылын, анда кеше йортында калган улы Хамматны сагыну газабы телә йөрәген. Өйләнеп, гаиләсе белән яңа өй салып башка чыккан Хаммат әнисен үз янына ала. Әсәрне укып чыккач, Шәмсенаһар әбинең олы җанлы, изге күңелле, риясыз, тыйнак, кешеләргә гел яхшылык кына эшләргә омтылган кеше булуына

тагын бер кат инанасың. Шундый булмаса, Зилә белән Марат әбиләренең китүен шулай авыр кичерерләр идемени? “Бу төн йортны кара кайгы чорнагандай тоелды. Беркем ашамады, эчмәде. Иң кадерле кешесез калудан туган сагыш ике баланың да йөрәгенә таш сыман утырды” [6, 142] . Юкка гына автор әсәрен “Югалту ачысы” дип атамагандыр. Әдәбият белгече Әлфия Мотыйгуллина фикере белән дә килешми мөмкин түгел. “Укучыларны алар (Р.Рахман әсәрләре) югары әхлаклы геройлары, бигрәк тә зур авырлыкларга дучар ителеп тә, яшәү мәгънәсен югалтмаган хатын-кыз образлары белән җәлеп итте”, дип яза ул [5, 6].

**Геройларның прототиплары**

Һәрбер әдәби персонажның прототибы, ягъни тормыштагы реаль кешесе булганлыгы билгеле. Ул кайчак авторның үзе, кайчак тарихи шәхес, ә кайчак авторның танышы, туганы булырга мөмкин. Әдәбият белгече М. Мещерякова фикеренчә: “Прототип – реаль кешенең копиясе түгел, ә типик әдәби образ тудыру өчен нигез генә булып тора”.[2, 184].

Рифә Рахманның “Югалту ачысы” әсәре образларын анализлаганда да без “прототип” төшенчәсен кулланырга тиешбез, чөнки кыйссада без ишетеп белгән вакыйгалар, реаль кешеләр турында сөйләнә. Андагы геройларның кайберләренең исемнәре бераз үзгәртелгән, кайберләренеке үзгәртелмичә дә бирелгән. Исеме үзгәртелмичә бирелгән герой - Шәмсенаһар әби. Әсәрдә әтисенең исеме Габидулла дип бирелгән. Чынлыкта ул Нәҗип кызы Шәмсенаһар 1904 нче елда Адай авылында туган. Бик иртә әнисез калып, бала вакыттан ук бөтен хатын-кыз эшен үзенә башкарырга туры килгән. Нәкъ әсәрдәгечә, энесе Гарифны карау да аның өстендә булган. Дөрестән дә, Шәмсенаһар әбинең Гариф исемле туганы булган. Ул Малмыж шәһәрендә яшәгән, хатыны Оркыя белән ике ул үстергәннәр.

Шәмсенаһар 1938 нче елда Сәрдекбаш авылы егете Камалетдинов Билалга кияүгә чыга. Әсәрдә бу вакыйга болай тасвирлана: “...күрше Чалпыбаш авылының үзе шикелле үк ябык, озын буйлы егетеннән аңа яучылар килеп төште. Шәмсенаһар, ялгыз калудан бик курыкканга, шунда ук ризалыгын бирде... Шакир сабыр холыклы, аз сүзле, гаилә эчендәге ыгы-зыгыдан бик туйган күркәм холыклы бер егет иде. Шәмсенаһарны да үзенә охшаганлыгы өченме, ул бер күрүдә яратты” [6, 141]. Шәмсенаһар һәм Билал Камалетдиновларның 1939 нчы елда уллары Самат туа. Әсәрдә ул Хаммат исеме белән бирелгән. 1941 нче елда ук сугышка киткән Билал кире әйләнеп кайтмый. Кайда һәлак булганлыгы да, җирләнгән урыны да билгесез.

Шәмсенаһар тормышында зур роль уйнаган тагын бер герой – укытучы Фәйзрахманның прототибы да билгеле. Ул 1951-1957 нче елларда Сәрдекбаш җидееллык мәктәбендә математика укытучысы булып эшләгән Сабирҗанов Фәтхрахман абый – Рифә Рахманның әтисе. Әсәрдә шәфкатьлелеге, кешелеклелеге белән укучы күңелен җәлеп иткән бу образның прототибы да нәкъ шундый сыйфатларга ия булган. Мәктәбебезнең ветеран укытучысы Нәбиева Вәрәкыя Фатих кызы истәлекләреннән: “Фәтхрахман абый безгә математика укытты. Үз фәнен биш бармагыдай белә торган бик белемле укытучы иде. Теманы һәрвакыт тормыш белән бәйләп аңлатты. Бер мисалы әлегәчә исемдә. "Дегет чиләгеннән башка арба бармаган кебек, ваклаучыны да санаучыдан аерырга ярамый",- дип әйтергә ярата иде ул. Үзем мәктәптә эшли башлагач, өлкән укытучылар Янил мәктәбеннән ачык дәресләрдән кайту вакыйгасын сөйләгәннәре хәтердә. Яз көне, Бөр елгасының ташыган вакыты була. Иртә белән исән булган күперне көндез кайтышларына ташу алып китә. Шунда Фәтхрахман абый, өстен чишенеп, хатын-кыз укытучыларны җилкәсенә кочып, аргы ярга чыгара. Ул безгә, укучыларына карата да бик гадел, мәрхәмәтле, туры сүзле булып истә калган”.

Кыйссада Шәмсенаһар әби карап үстерешкән балалар Марат белән Зиләнең Фәтхерахман Сабирҗанов балалалары Ренат Сабирҗанов һәм авторның үзе, ягъни Рифә Рахман икәнлеге дә аңлашыла. Балалар әбиләре белән аерылышуны авыр кабул иткән кебек, Шәмсенаһар әби дә бу хәлне авыр кичергәндер, юкса 1975 нче елда туган оныгына Ренат исеме куштырмас иде. Камалиев Ренат абый яшәгән йортта Рифәнең бала вакыттагы фоторәсеме әле бүген дә саклана. Шәмсенаһар әби аны Мәмәширдән кайтып киткәндә үзе белән истәлеккә алгандыр, сагынган вакытларында кулына алып, озаклап карагандыр. Аны

белгән кемнән генә сорасаң да, Шәмсенаһар әбинең бик тә бала җанлы, эчкерсез, юаш табигатьле, мәрхәмәтле булуын сөйлиләр. Рифә Рахман аны нәкъ шулай итеп сурәтләгән дә. Шундый булмаса, Зилә (Рифә) күп еллар үткәч, инде әбисе бакыйлыкка күчкәч, аны сагынып, өе каршысындагы чишмә янына килмәс иде, аны уйлап, тау башындагы чирәмдә моңаеп утырмас иде. “Әгәр, сукмагыннан төшеп, әбисе эчкән чишмәнең суын татысаң, көмеш тамчыларында югалту ачысы бар микән?” [6, 145] дигән сүзләрдә сагыш, кайтарып булмаслык югалту газабы, әрнү сизелә.

Шәмсенаһар әби улы Самат, килене Рәҗәбә (Минехода) тәрбиясендә яшәп, 1980 нче елда каты авырып үлеп китә. Килене белән бик тату торулары, икесенең һәр эшне киңәшләшеп эшләүләре турында сөйлиләр оныклары. Әби авырып, Зур Сәрдек участок больницасында ятканда да, аны килене саклаган, тәрбияләп, хөрмәтләп, соңгы юлга озатучылар да Самат абый белән Минехода апа булган. Бүген инде алар үзләре дә исән түгел. 70 яшьләрен дә тутырмыйча, бер-бер артлы (3-4 кенә ай аерма белән) авырып бакыйлыкка күчтеләр.

**Әсәрдә топонимнарның бирелеше**

Без шулай ук әсәрдә авторның топонимнарны бирү үзенчәлегенә дә игътибар иттек. Кайбер географик атамалар әсәрдә үзгәртелмичә бирелә. Мәсәлән, Малмыж, Китәк атамалары. Шул ук вакытта реаль атамаларга нигезләнеп, бераз үзгәртеп бирелгән, ләкин кайсы авыл турында сүз барганлыгы җиңел аңлашыла торган авыл исемәре дә очрый. Мәсәлән, Түшшел (Кукшел), Гөбәер (Мәмәшир), Чалпыбаш (Сәрдекбаш). Кайбер авыл исемнәрен, кыйссаның эчтәлегеннән чыгып, фаразларга мөмкин. “Шәмсенаһарны күрше авылдагы нindидер чирмеш-әкәйгә бала карарга урнаштырдылар”, дигән юллардан бу авылның Китәк икәнлеге аңлашыла. Чәнки Шәмсенаһар әби туып-үскән Адайга иң якын мари авылы Китәк икәнен беләбез. Алга таба Р.Рахман: “Шәмсенаһар, Микулай абзасында торганда, татар авылындагы яңача укыткан хәлфәгә берничә дәрескә барган..., әмма ара ерак булгач, үзе үк мәктәпкә йөрүдән туктаган иде” [6, 140], дип яза. Китәккә бик үк якын булмаган бу авылны электән үк мәгърифәт үзәге булган Мәчкәрә дип фаразларга мөмкин. Шулай ук автор яратып, матурлыгына сокланып тасвирлаган Чалпыбаш авылындагы “мул сулары тыштагы улакларга агып чыгып, очан су булып югарыга күтәрелүче” чишмә – һичшиксез, Сәрдекбаш авылының Мөхәррәм чишмәсе булырга тиеш. “Аста, бераз түбәндәрәк, тирәкләр арасында мәчет сыман эшләнгән йорт эчендә әбисе дә сукмагыннан көн дә төшкән чишмә ургып утыра. Менә нинди матур урында яшәгән икән ул!” - дип яза Рифә апа. Дөрестән дә, Шәмсенаһар әби яшәгән йорт каршында яшел чирәмле калкулык, ә калкулык астындагы инеш буенда искиткеч матур, саф сулы чишмә бар. Тирә-якта беренчеләрдән булып, Сәрдекбашның алтын куллы остасы Ихсанов Мөхәррәм абый чишмәне матурлап, мәчет кебек манаралы йорт эченә урнаштыра. Узган гасырның сиксәненче елларында ук бу чишмәнең фотосы “Сөембикә” журналында (ул чагында “Азат хатын”) басыла. Шуннан соң Татарстан авылларында күп чишмәләрне Мөхәррәм абый стилендә эшли башлыйлар.

Р.Рахманның “Югалту ачысы” кыйссасын, аның геройларын, әдәби образларның прототипларын өйрәнгәннән соң түбәндәге нәтиҗәләр ясалды:

1. Р.Рахман бу әсәрне реаль кешеләрне һәм алар белән булган реаль вакыйгаларны күздә тотып иҗат иткән. Кыйссаның төп герое, исеме үзгәртелмичә бирелгән Шәмсенаһар әби тормышта да, автор сурәтләгәнчә, бик ягымлы, изге күңелле, риясыз кеше булган.

2. Дөрестән дә, Шәмсенаһар әби, Сәрдекбаштан китеп, Рифә Рахманнар гаиләсендә яшәгән. Күп еллар үткәч, Р.Рахман аның турында әсәр иҗат иткән икән, димәк ул үзенең күркәм холкы, кешелеклелеге белән алар күңелендә тирән эз, матур истәлекләр калдырган.

3. Әсәрдәге башка геройларның да прототиплары бар. Алар һәрберсе Шәмсенаһар образын тулырак ачарга ярдәм итәләр.

Гомумән, Рифә Рахман гади авыл карчыгын кешелеклелеге белән гүзәл дә, кабатланмас та булган әдәби образ дәрәҗәсенә күтәргән. Әсәр укыла барган саен Шәмсенаһар үзенең яңа, күркәм сыйфатлары белән ачыла, соклану уята, ихтирам хисе

тудыра. Безнең уйлавыбызча, әсәрне укыган беркем дә аңа битараф калмас. Ә инде аның Сәрдек-Баш авылыныкы булуы безнең өчен икеләтә горурлык.

*Кулланылган әдәбият:*


1. Әдәбият белеме сүзлеге. Казан, Татарстан китап нәшрияты,1990.
2. Әдәбият белеме. Терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге. Казан, “Мәгариф” нәшрияты, 2007.
3. Җиһаншина З.Н. “Якташым турында берничә сүз” Мәйдан. 2012. №9.
4. Мещярекова М. Литература в таблицах и схемах. Теория. История. Словарь. Москва: Айрис-Пресс, 2004.
5. Мотыйгуллина Ә.Р. “Милли идеаллар сагындагы сүз” , Р.Рахманның “Йолдызлар төстән язганда” китабы. Казан, Татарстан китап нәшрияты, 2013.
6. Рахман Р.Ф. “Айлы күлдәвекләр”. Казан, Татарстан китап нәшрияты, 2006.
7. “Хәтер” китабы. Казан, 1995.


## МӘСӘЛ- ЯШЬ БУЫНГА ТӘРБИЯ БИРҮДӘ КЫЙММӘТЛЕ ЧЫГАНАК


*Фахрутдинова Зәлия Зөлфәтовна, 7нче сыйныф укучысы*
*Кукмара ш.т.п. Ч.Т.Айтматов исемендәге 1 нче гимназия,*
*Фәнни җитәкче: Мөхәмәтҗанова Флүзә Нурисламовна,*
*педагог-оештыручы*


Матур әдәбият элек-электән үк матурлык, зәвык, игелек тәрбияләүче чара булып саналган. Әдәби әсәрләрдә чагылыш тапкан вакыйгалар аша начарлык һәм яхшылык, матурлык һәм ямьсезлек, изгелек һәм усаллык, түбәнлек һәм бөеклек төшенчәләре яхшырак аңлашыла, аларны бер-берсеннән аеру, үз-үзеңне тотышыңа игътибар итеп камиллеккә омтылырга мөмкинлек бирә, мөһим тәрбия чарасы булып тора. Гомумиләштереп әйтсәк, кешенең рухи дөньясын формалаштыруда, аны яшәешне, тормышны күзалларга, бәяләргә өйрәтүдә матур әдәбиятның роле бик зур. Әле дөньяга карашы, әйләнә-тирәдәгеләргә мөнәсәбәте формалашып кына килүче сабыйлар өчен язылган әсәрләрнең әһәмияте бигрәк тә югары. Юкка гына балаларга атап төрле жанрларда әсәрләр иҗат ителмәгән, күрәсең.

Балалар өчен иҗат ителгән әсәрләр аеруча нәзәкатьле, самими, ихлас һәм гади булалар. Шуңа күрә сабыйлар өчен теләсә кем иҗат итәргә сәләтле түгел, бу эшкә бары тик балаларны яраткан, аларның психологиясен аңлаганнар гына алына. Ә укытучылар, балаларның иҗат мөмкинлекләрен үстерүгә зур игътибар биреп, тәрбия эшендә халкыбызның күркәм традицияләренә ныграк таяналар.

Мәсәлләр борынгы заманда ук барлыкка килгән. Алар гыйбрәт алу, әһәмиятле фикер әйтү өчен языла. Мәсәлләр һәрвакыт нәрсәгәдер өйрәтәләр, тискәре сыйфатларны тәнкыйтьлиләр, көләләр.

Фәнни тикшеренү-эзләнү эшебезнең **актуальлеге** шунда: мәсәлләр халык массасына, бигрәк тә яшь буынга тәрбия бирү чарасы булуы белән бергә, әйләнә-тирә дөньяны танып белү чыганагы буларак та хезмәт иткән һәм итә. Укучылар бу мәсәлләрне укып, әхлак тәрбиясе һәм тормыш тәҗрибәсе алалар.

**Каршылык:** мәсәлләрне өйрәнүгә мәктәп программасында вакыт әллә ни күп бирелми. Мәсәлләрне һәрвакытта да укыйбызмы? Аның моралең дөрес табабызмы? Бу **проблема** башлангыч сыйныф әдәби уку дәреслекләрендә бирелгән мәсәлләрдә ачык күренә.

Чыгышымның **темасы:** “Мәсәл- яшь буынга тәрбия бирүдә кыйммәтле чыганак” дип атала. Хезмәтнең **максаты:** мәсәлләрнең башка жанрлардан аермасын билгеләү һәм әдәби уку дәресләрендә аларны өйрәтүдә иң отышлы алымнарны ачыклау.

**Өйрәнү объекты:** гомумбелем оешмаларында шәхес тәрбияләүдә мәсәлләрне өйрәнү процессы.

Мәсәл жанрын өйрәнеп, аларны укыганнан соң, һәр укучы төрле яктан тәрбияле булыр дип **фаразлыйбыз.**

Алда куелган максатлардан чыгып, түбәндәге **бурычлар** билгеләнде:

- алынган теманы әдәби һәм фәнни чыганаклардан барлау;
- хезмәтнең теоретик һәм гамәли әһәмиятен күрсәтү;
- балаларга мәсәлләрне өйрәтүдәге иң уңышлы метод һәм алымнарны ачыклау.

**Тикшерүнең методы:** эш барышында эзләнү, күзәтү, әңгәмә, барлау, анализлау, нәтиҗә ясау, гомумиләштерү кебек методлар кулланылды.

**Фәнни яңалыгы:** бүгенге көнебездә мәсәлләрнең әдәбиятта токтан урынын барлау.

Мәсәлләрнең килеп чыгуы безнең эрага кадәр V гасырга карый. Аны уйлап табучы булып кол Эзоп (б.э. кадәр VI–V г. яшәгән) санала. Аның башкача үзенең фикерләрен белдерергә мөмкинлеге булмаган. Үз фикерләреңне икенче төрле формада бирү соңрак "эзоп теле" дип тә атала башлый. Тик безнең эрага кадәр II гасырда гына мәсәлләрне язып бара башлыйлар, шул исәптән Эзоп мәсәлләрен дә.

Антик чорда күренекле мәсәлче булып борынгы Рим шагыйре Гораций (б.э. кадәр 65–8 г.) таныла.

XVII–XVIII гасыр әдәбиятында антик сюжетлар эшкәртелүгә дучар булган.

XVII гасырда француз язучысы Лафонтен (1621–1695) яңадан мәсәл жанрына мөрәҗәгать итә. Жан де Лафонтенның мәсәлләре нигезендә Эзоп мәсәлләренең сюжеты ята. Әмма француз мәсәлчесе, антик мәсәлнең сюжетын кулланып, яңа мәсәл барлыкка китерә. Антик авторлардан аермалы буларак, ул уйлана, сурәтли, дөньяда барган күренешләргә бәя бирә, укучыга кырыс рәвештә үгет-нәсихәт бирми. Лафонтен күбрәк геройларның хисләренә игътибарын юнәлтә, сатира белән акыл өйрәтү арткы планга чыга.

XVIII гасырда Германияда мәсәл жанрына шагыйрь Лессинг (1729–1781) мөрәҗәгать итә. Эзоп шикелле, ул да мәсәлне проза белән яза. Ә менә француз шагыйре Лафонтенның мәсәлләре грациоз новелла булалар. Алар "поэтик уен" белән орнаментлашкан булалар. Бу, Лессинг мәсәле белән әйтсәк, аучы угы шикелле була. Матур орнаментлар белән бизәлгән аучы угы үзенең беренчел ни өчен кулланылган икәнлекне оныттыра. Лессинг Лафонтенга әдәби сугыш игълан итә. "Мәсәлдәге сөйләм, мөмкин булганча кыскартылырга тиеш. Бизәк һәм фигуралардан азат булырга, ачык булырга тиеш", - дип яза ул [32, б.105].

Рус әдәбиятында милли мәсәл традициясенә нигез салучы - А.П.Сумароков (1717–1777). Аның поэтик девизы: "Доколе дряхлостью иль смертью не увяну, Против пороков я писать не перестану..." була. Мәсәл жанрының үсешендә иң югары нокта булып И.А.Крылов (1769–1844) мәсәлләре тора.

Моннан тыш, ироник, пародияле мәсәлләр К. Прутков, А.К.Толстой, бертуган Жемчужниковлар иҗатында бар. Демьян Бедныйның иҗатында революцион мәсәлләр дә очрый.

Мәсәл - аллегорик характердагы, ягъни читләтеп әйтүгә, кинаягә корылган гыйбрәтле, акыл-әхлак өйрәтүле кечкенә хикәя.

Мәсәлләр — бала тәрбияләүдә бай материал булып исәпләнә. Нинди дә булса акыл, гыйбрәткә бай булуы белән бу әсәр балаларны тормышка әзерли.

Мәсәлдә, нигездә, уңай тәэсирләр уята торган вакыйгалар сурәтләнә. Яхшылык һәрвакыт явызлыкны җиңә, геройларның төп сыйфатлары булып батырлык, өлкәннәргә хөрмәт, намуслылык, яхшы күңеллелек санала. Куркактан, әләкләүчедән, ахмактан көлгән мәсәлләр дә балага әхлак тәрбиясе бирүдә зур роль уйный. Баланың мәсәлне тыңлаганда мәгънәсенә төшенүе, идея эчтәлеген дөрес аңлавы зарури.

Мәсәлнең жанр сыйфатларын билгеләгән төп сыйфатлар:

- сюжетлылык, вакыйганың кыска һәм җыйнак, билгеле бер фикер әйтү өчен үткенәйтелгән булуы.
- аллегориягә, кинаягә корылу.

Кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрне, билгеле бер мораль сыйфатларны гәүдәләндерү өчен, кагыйдә буларак, персонажлар итеп хайваннар, җәнлекләр, балыклар, кошлар, үсемлекләр сурәтләнә. Кайчагында җансыз предметлар алына.

Вакыйгалардан килеп чыга торган әхлакый нәтиҗә - мораль. Ул мәсәлнең башында я азагында бирелә. Әсәрдән чыга торган фикер ап-ачык аңлашылып тора икән, моральнең булмавы да мөмкин. Төп фикер идея-әхлакый, сатирик һәм ироник характерда булуда.

“Татар теленең аңлатмалы сүзлеге”ндә мәсәл, аллегория, иронияга нинди аңлатмалар бирелгәнлеген карап китик:

*Мәсәл* – кешеләргә, кеше тормышына киная белән хайваннар яки җансыз әйберләр турында сөйли торган, күбесенчә вәгазь,үгет-нәсихәт белән тәмамланган кыска шигъри хикәя.

*Ирония* – 1. читләтеп, мыскыллап, астыртын көлү. 2. Берәр кешене яки әйберне мактаган булып, алардан яшертен көлүдән торган стилистик әйләнмә яки сүз.

*Аллегория* – конкрет сәнгать образлары ярдәмендә абстракт төшенчәләр белән белдерү, киная [10, б.16].

Мәсәл - бик борынгы жанр. Ул үзенең тарихи үсешендә төрле этапларны үткән. Баштарак ул сөйләмдә гади мисал, чагыштыру буларак кулланыла. Алга таба иҗтимагый тормышта теге яки бу катлаулы ситуациядән чыгу юлын күрсәткән өйрәтмә, киңәш рәвешендә мөстәкыйльлек ала.

Мәсәлләр халык иҗатыннан мәкаль һәм әйтемнәр белән тыгыз бәйләнештә булып, теге яки бу “канатлы” гыйбарәдән яки сүздән үсеп чыкканнар. Кайвакыт киресенчә, “канатлы” сүз барлыкка килү өчен нигез булып торалар. Бу күренеш мәсәлләрне халык авыз иҗатына якыйнайта да инде.

Мәсәл ул- тормыштагы гыйбрәтле яки кимчелекле күренешләрне, капма-каршы холык сыйфатларын аллегорик образлар бәрелешендә күрсәтә, әхлакый гомумиләштерү белән тәмамлана торган әсәр.

Мәсәл үзенчәлекләренең берсе булып аллегория тора. Шартлы образлар аша билгеле бер социаль күренешләр күрсәтелә. Шулай, еш кына Арыслан образында еш кына деспотизм, явызлык, гаделсезлек бирелә. Төлке – хәйләкәрлек һәм ялганлык синонимы.

Мәсәл ахырында (кайвакытта башында) автор зур булмаган сүз бирә. Анда укучыга юнәлгән төп фикер, ягъни мораль була.

Мәсәлнең жанр сыйфатларын билгеләгән төп сыйфатлар:

- Сюжетлылык, вакыйганың кыска һәм җыйнак булуы;
- Аллегориягә корылу;
- Тормышта очрый торган кимчелекләр тәнкыйть ителү;
- Сюжетның (вакыйганың) шартлы булуы;
- Тасвирый өлеш һәм әхлакый нәтиҗә- моральдән торуы;
- Кыска күләмле лиро –эпик әсәр булуы.

1. Мәсәлдә сюжет төгәлләнгән һәм җыйнак була, аларда өстәмә детальләр, чигенешләр очрамый диярлек. Сюжет еш кына диалог формасында бирелә. Вакыйга билгеле бер фикерне әйтү өчен үткенәйтелгән була.

2. Аллегориягә корылу дигән сүз түбәндәгене аңлата: кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрне, билгеле бер мораль сыйфатларны гәүдәләндерү өчен, кагыйдә буларак, персонажлар итеп хайваннар, кошлар, үсемлекләр сурәтләнә, кайчагында җансыз предметлар да алына.

3.Һәр мәсәлдә нинди дә булса тормышта очрый торган хәлләр тәнкыйтьләнә.

4. Нәкъ менә тәнкыйть итү максатыннан шартлы вакыйгалар алына да инде.

5.Төп бүлектә вакыйга турында сөйләм бирелә, персонажлар арасында мөнәсәбәт, конфликт ачыла һәм шуннан соң авторның әлеге хәлләргә мөнәсәбәтен чагылдырган, образларның чын йөзләрен аңларга ярдәм иткән бетеме килә.

6. Лиро –эпик әсәр үзендә эпик һәм лирик әсәр сыйфатларын туплый. Ул эпостан хикәяләү, сюжетлылык, персонажлар системасы хәрәкәт итү кебек үзенчәлекләрне; лирикадан тезмә форма, кече формага омтылуны үз эченә ала.

В.А.Жуковский "О басне и баснях Крылова" мәкаләсендә мәсәлнең дүрт үзенчәлеген күрсәтә.

Беренчесе – характер үзенчәлеге. Бер хайван икенчесеннән нәрсәсе белән аерылып тора. "Хайваннар кешене күрсәтә. Ләкин ул кеше ниндидер мөнәсәбәтләрдә тора. Шул исәптән һәр хайванның үзенең аерылгысыз характеры була. Кеше берәр хайван турында сүз чыкканда, шунда ук ул хайванның характерын күз алдына китерә. Бүре дигәндә – канэчкеч ерткыч, Төлке дигәндә – ялагай яки ялган кеше күз алдына килә" [12, б.68].

Шулай итеп, Ишәк – аңгыралык, Дуңгыз – шапшаклык, Чикерткә җилбәзәклекне гәүдәләндерә. Жуковский фикеренчә, мәсәлнең бурычы- укучыга авыр көнкүреш ситуацияләреннән гади генә мисаллар үрнәгендә чыгарга булышу. Жуковский язганча, мәсәлнең икенче үзенчәлеге – "укучыны уйлап чыгарылган яңа хыялый дөнья белән таныштыру. Уйлап чыгарылган образлар ярдәмендә чынбарлыктан көлеп, ләззәт кичерү". Ягъни укучы уйлап чыгарылган вакыйгаларны геройлар белән бергә "яши" ала [12, б.26].

Мәсәлнең өченче үзенчәлеге – үгет-нәсихәт дәресе, мораль, персонажның тискәре сыйфаты. "Мәсәл – үгет-нәсихәт дәресе ул. Җанландырылган предметлар һәм хайваннарны карап, укучы үз-үзенә бәя биреп утыра.",- дип яза Жуковский [12,б.113]. Дүртенче үзенчәлек – мәсәлдә кешеләр урынына хайваннар һәм предметлар хәрәкәт итә. "Без сәхнәдә кешеләрне күрергә иялэнгән. Ә монда табигатькә тагын да якынаябыз, сурәтләнгән күренешләрдән моральны аңлыйбыз" [12, б. 34].

Мәсәлләрдәге персонажлар эш-гамәлләре, сөйләмнәре белән үз холыкларын үзләре үк ачалар ( "Мин диңгездә йөзәм, һавада очам, җирдә йөгерәм", -дип мактана үрдәк). Кайвакыт бу характеристика икенче персонажлар сүзе белән дә тулыландырыла ("Син матурсың-сүзем юк,тик менә миннән башка салават күпере була аламы соң?",-дип кисәтә Кояш). Кайчак автор үзе дә бер-ике сүз белән генә булса да характеристика бирүдә катнаша ("Аю, ахмак, ике ел да гакыллы карттан алданды", М.Гафури). Шуңа да мәсәлләрнең вакыйгалары кыска, драматик, ул кечкенә пьесага охшый.

Мәсәлләрнең эчтәлеге мөһим әхлак проблемаларын һәм аларны чишү буенча акыллы киңәшләр бирүне күздә тота. Мәсәлнең аңлаешлыгы аның характерлы жанр үзенчәлекләренә кайтып кала.

Мәсәлләрне язучылар, шагыйрьләр үзләренчә сөйләп килгән. Мәсәлне оста язучылар булып, татарларда Каюм Насыйри, Таиб Яхин, Габдулла Тукай, Мәҗит Гафури, Әхмәт Исхак, Габдулла Шамуков, руслардан Иван Крылов һәм французларда Жан де Лафонтен санала.

XX йөз башы татар әдәбиятында Г.Тукай һәм М.Гафури иҗатларында мәсәл жанры зур үсеш ала. Аларның мәсәлләре ике төп юнәлештә үсә: 1) халык иҗаты сюжетына таянып иҗат ителгән үгет- нәсыйхәт рухындагы мәсәлләр; 2) астыртын көлү, сарказмга таянып, чорның иҗтимагый- сәяси тормышын сурәтләүче мәсәлләр.

Г.Тукайның укыту-тәрбия өлкәсендәге карашлары елдан-елга төгәлләшә, ачыклана бара, аның үз мөнәсәбәте барлыкка килә. Ул милли мәктәптә тәрбия бирү мәсьәләләре турында уйлана башлый. "Фикер"нең 1907 ел саннарында эчтәлеге һәм язылыш рәвеше белән Л.Н.Толстойның "Педагогик хатлар"ын хәтерләткән "Ана мәктүбеләре" исемле бик кызыклы язма бастыра. Биредә әдип, татарларда бала тәрбияләгән вакытта, тән ягыннан гына түгел, аң, акыл, күңел ягыннан да тәрбияләргә, үстерергә кирәклегенә басым ясый.

Г.Тукай, әхлак тәрбиясе бирүне беренче урынга чыгарып, нәкъ менә кечкенә хикәятләр, шигырьләр, мәсәлләрнең тәрбия өлкәсендә файдалы булуына басым ясый, "тәрбия гыйлеменең күп яңа тәҗрибәләре мондый хикәятләрнең балаларның әхлагына әллә нинди вәгазьләрдән дә гүзәл тәэсир иткәнлеген бик ачык сурәттә күрсәтмештер. Хикәятләрнең бу тәэсире ислам галәмәсенә бик күптәннән бирле мәгълүм булып килгән бер кагыйдәдер".

Кереш сүздә хрестоматия белән эшләү вакытында кулланыла торган ысул һәм алымнарга да тукталына:

1. Балаларда укыган нәрсәләрен игътибар белән уку һәм аңларга тырышу мәләкәсен хасил иттерер өчен, кыйсса укылып тәмам булгач, сыйныфтагы бер-ике баладан, үз сүзләре белән, эчтәлеген сөйләтеп чыгу;

2. Укылган кыйссаларга, балалар зиһенендә туа торган сорауларга шул кыйссаның үзеннән үк җавап табарга өйрәтү шундыйлардан. Өченче метод-әңгәмәгә киңрәк тукталып, аның үрнәге китерелә:

Мисал өчен “Картайган Арыслан” кыйссасына тукталып үтәргә мөмкин.

-Бу кыйссадан нәрсәне аңладыгыз, балалар?

-Арыслан картаеп көчсезләнгән, хайваннар һәммәсе аның бу көнгә калуыннан шатланып, иске ачуларын алырга җыенганнар.

-Болар арасында нинди хайваннар булган?

-Хайваннар күп булганнар: ат та булган, бүре дә, үткен мөгезле үгез дә, хәтта ишәк тә булган. Алар һәммәсе Арысланнан усаллык күргән булганнар.

-Ник әүвәл вакытта моннан ачуларын алмаганнар соң?

-Көчләре җитмәгән.

-Әгәр Арыслан сау, көчле вакытында бу хайваннарга зарар китермәгән булса, хәзер хәлсезләнгәч, картайгач, аны болай газапларлар идеме?

-Юк.

-Ник?

-Үзенең берәүгә дә зарары тимәгәч, аны ник газапласыннар?!

-Алай булгач, Арыслан әгәр картайган, көчсезләнгән көнендә җәбер күрәсе килмәсә, нишләргә кирәк иде?

-Сау, көчле вакытында башкаларга зарар итмәскә кирәк иде.

-Арысланга кемнең җәбере авыр тоелган?

-Ишәкнеке.

-Ник?

-Чөнки ул ишәкне бик зур күреп йөргән, үзенең шулкадәр зур күреп йөргәне, онытучысыннан җәбер күрү бигрәк уңайсыз булган.

-Әгәр җәбер күрәсе килмәсә, үзе нишләргә тиеш иде?

-Аңа җәбер итмәскә кирәк иде.

-Шулай булгач, балалар, кемнең башкалардан җәбер күрәсе килми, ул кеше үзе дә башкаларга җәбер тидермәскә кирәк. Бигрәк тә үзеңнән көчсезләргә җәбер тидерүдән сакланырга кирәк.

Үрнәк әңгәмәдән күренгәнчә, ул әсәрдәге әхлакый мәгънәне балага җиткерү максаты белән кулланыла, “үзеңнең рәҗетеләсен килмәсә, башкаларны да рәнҗетмә” дигән фикерне, үгетне аңлатып бирә.

Мәҗит Гафури татар әдәбиятында мәсәлне алып керүче, үстерүче булып танылa. Г.Тукай һәм М.Гафури иҗатында мәсәл ике төп юнәлештә үсә: 1) халык иҗаты сюжетына таянып иҗат ителгән үгет- нәсыйхәт рухындагы мәсәлләр; 2) астыртын көлү, сарказмга таянып, чорның иҗтимагый- сәяси тормышын сурәтләүче мәсәлләр. Хәзерге вакытта да иҗат ителү туктамый, күбрәк сәяси мәсәлләр язалар. Шулай ук XX йөз дәвамында Н.Исәнбәт, Г.Афзал, Ш.Галиев, Ә.Исхак һ.б. мәсәл жанрын баетуга үз өлешләрен кертәләр.

Татар әдәбиятында мәсәл жанрында актив иҗат итүче, аңа нигез салучыларның берсе – Мәҗит Гафури. Мәсәл хайваннар һәм предметлар дөньясы фонында кешеләр мөнәсәбәтен нечкә киная белән ачарга мөмкинлек бирә.

Гафури 1907 һәм 1914 нче еллар арасында 25 тән артык мәсәл язган. Үзләренең эчтәлекләренә карап, аларны ике төп төркемгә бүләргә мөмкин: берсе – политик мәсәлләр, икенчесе – мораль мәсәлләр. Беренче тип мәсәлләрдә чагылган төп идея – өстен катлауларның законсызлыгын, көчсезләрне гаепсезгә хөкем итүләрен һәм шулар исәбенә яшәүләрен күрсәтү тора. Гафуриның берничә мәсәлендә патшалык проблемасы алына.

Патшалык белән изелгән халык арасындагы мөнәсәбәтнең бер чагылышын “Сандугачлар” һәм “Әтәч белән сандугач” мәсәлләрендә дә очратабыз. Монда тоткынлык һәм ирек мәсьәләләре куела. Сандугач көне-төне читлектә утыра, аңа җим бирәләр. Аның тамагы тук. Аңа әтәчнең иркендә чүплек башыннан җим эзләп йөрүе бик сәер тоела, һәм ул ирекле әтәчтән үзенчә көлә. Читлек эченә бикләнгән сандугач образында М.Гафури, һичшиксез, патша хөкүмәт тарафыннан тамак хакына, иреге чикләнгән, шушы язмышка канәгать булган, патшага яки байларга сатылган җырчыларны, яисә шагыйрьләрне күрсәтә һәм тәнкыйть итә. Ирекле яшәүчене ирегең ашау – эчүгә сатып ирексез яшәүчедән өстен күрә.

Сандугачлар- халык. Беренче мәсәлдә карчыганың сандугачларга һөҗүм итеп, аларны канга батырып таратуы – нәкъ 1905 нче елгы революция көннәрендә самодержавиянең революцион халыкка ясаган канлы погромын чагылдыра.

Гафуриның халыкны сандугач итеп алуы да халыкның гаепсез бер гүзәл көч икәнлеген күрсәтә торган образ булып йөри.

“Сарыкны кем ашаган?” һәм “Эт белән куян” мәсәлләрендә дә закон тарафыннан якланылмаган һәм куяндай ярдәмчесез халыкка “эт этлеге”, “бүре комсызлыгы” белән һөҗүм итүчеләрнең ерткычлыгы күренә.

Икенче группага, ягъни кешеләр җәмгыятендәге мораль мәсьәләсенә караган мәсәлләрне дә шагыйрьнең берничә идеологик тенденциясе нигезендә төркемләп карарга мөмкин. Шулар арасыннан “ Ишәк” һәм “Алмаз ташы” мәсәлләрендә, гомумән алганда, наданлык һәм укыганлыкны, аерым алганда, түбән җәмгыять белән мәгърифәтне һәм интеллигентны чагыштыру тора. Гафури боларда гакылны, белемне, тормышны аңламаучы “ишәк төсле кешеләрне” тәнкыйтьли һәм мәгърифәтче гуманист интеллигентны аңламаган наданнарның дөньяда яшәүләренә үкенеп карый.

Наданлык, ялганлык һәм ахмаклык начарлыгын күрсәтүче гомуми мораль үгетен бирүгә “Маймыл белән күзлекләр”, “Бабай белән аю”, “Тавык белән үрдәк”, “Ат белән эт”, “Чикерткә белән кырмыска” мәсәлләре багышланган.

Мәҗит Гафури мәсәлләр язганда, тема сайлауга, әдәби осталыкка И.А.Крыловтан өйрәнә. Хәтта байтак кына мәсәлләрен, “Маймыл белән күзлекләр”, “Җанварларга килгән үләт”, “Патша сайлау” аңа ияреп иҗат итә. Кош-кортмы, хайваннармы – нинди генә образ булмасын, шагыйрь аларны кешеләр характерын һәм мөнәсәбәтләрен гәүдәләндерә алырлык итеп бирә. Гафури реакция елларында һәм аннан соң да күп кенә мәсәлләр яза: шуларның байтагында ачык әйтергә мөмкин булмаган үткен иҗтимагый фикерләрен үткәрә, социаль гаделсезлекнең четерек күренешләрен фаш итә. (“Әтәч белән Сандугач” ).

Гафури мәсәлләрендәге вакыйгалар башлыча хайваннар һәм кошлар дөньясы әйләнә-тирәсендә алынып, кешеләр һәм хайваннар яки предметлар һәм кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрне сурәтләү формасындагылары азчылык тәшкил итә [11, б.117] .

Татар әдәбиятында күренекле мәсәлчеләрнең тагын берсе - Г. Шамуковның язучылык сәләтен сәхнә һәм театр ача. Әдәбият дөньясына театр аша сәхнә тәҗрибәсен алып килүе аның иҗатына да тирән эз сала: аның үзенчәлекле юнәлешен билгели, сәхнәгә якын торган жанрлар белән эш итүенә китерә.

Г. Шамуковның тәрҗемәче булып китүенә дә театр этәргеч ясый, театр булыша. Ул сәхнәдә уйнау өчен әүвәле Шекспирның “Отелло” сын (1944) тәрҗемә итә.

И. Крылов мәсәлләрен татарчага тәрҗемә итүдә дә иң актив эшләүчеләрнең берсе – Г.Шамуков санала. Бөек рус мәсәлчесенең 40 тан артык әсәрен тәрҗемә итү, 20 ләп әсәренең сюжетыннан файдаланып мәсәл язу факты да күп нәрсә сөйли.

Крылов мәсәлләрен тәрҗемә итү тәҗрибәсе, Эзоп, Гафури, С.Михалков һәм башка язучыларның мәсәлләрен сәхнәдән башкару, бу жанрның закончалыкларына тирәнтен төшенү һәм бай мөмкинлекләрен тою Г.Шамуковның үзенә дә мәсәл язу теләген уята. 50-60 нчы елларда “Чаян” һәм “Казан утлары” журналларында аның үзе иҗат иткән мәсәлләре күренә башлый. Сугыштан соңгы елларда татар поэзиясендә мәсәл жанрының җанлануы һәм үсүе турында сөйләгәндә , һич тә Г.Шамуков мәсәлләрен читтә калдыра алмыйбыз. Безнең

тормышны ямьсезләп, алга барырга комачаулаган гарип күренешләрне фаш итүдә ул мәсәлне искерми торган, үткен һәм сугышчан корал итеп файдалана. Мәсәлнең читләтеп әйтүгә, кинаягә нигезләнгән традицион алымнары аңа шактый кызыклы һәм гыйбрәтле вакыйгалар корырга мөмкинлек биргән.

Мәсәлнең мондый традицион образлары һәм алымнары аша яңа эчтәлек ачу Г.Шамуковның башка мәсәлләрендә дә очрый. “Арслан һәм Ярлык” мәсәлендә койрыгына ишәк дигән печатьле сургычлы ярлык тагылган мәгърүр арсланның фаҗигасе: үзенең арслан икәнлегенә бер киекне дә ышандыра алмый гаҗиз булуы, ахырда үзенең ишәккә охшап калуы турында сүз бара. Аның мәсәлләрендә гайрәтле аюлар янында телен тешләп, начарлыкны белсә-күрсә дә эндәшмичә йөрүче, эчеп алгач кына гайрәтләнеп аюны тетеп салган мыштым куяннар да, тавык фермасында эшләрнең рәте киткәннән соң, җәза аласы урында, кода-кодагыйлык аркасында казлар фермасына түрә итеп куелган төлке дә, тыныч кырмыскалар оясына барып кергән елан да бар. Кайвакытта автор сөйләнгән вакыйганың нәтиҗәсен үзе үк ачыктан-ачык әйтеп сала, кайвакытта фикернең җеп очын яшерә, укучының үзенә уйларга урын калдыра. Мәсәл фикерен персонаж сүзләре аша әйттерү алымын автор аеруча еш куллана.

Кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләр турында сөйләүче шундый аллегорик образлардан һәм шартлы вакыйгалардан тыш Г.Шамуков хәзерге заман мәсәлендә активлаша башлаган яңа алымнарны, әйтик, шигъри фикерне төрле предметлар аша яки турыдан-туры кешеләрнең үз образлары аша ачу алымын да куллана [25,б. 5] .

Татар әдәбиятында мәсәл жанрында шулай ук Әхмәт Исхак та эшли. Ул зур уңышка мәсәл жанрында ирешә. Талантының шул ягына басым ясап, С.Хәким Ә.Исхак турында:

“Әйтерсең, мәсәл жанры шагыйрьнең бушаганын озак вакыт көтеп торган. Мәсәлләр Ә.Исхакта үз кешесен тапты. Ул - үткен телле, шаян, шук, урынына карап, үтергеч усал. Бу жанрда ул үзен ничектер бөтенләй җиңел сизә, иркен тота, аның чын мәгънәсендә хуҗасына әйләнә. Минемчә, таланты аның шунда Тукайлардан, Гафурилардан соң мәсәлне яңадан безнең шартларда үстереп җибәрде ул”,-дип язган.

Ә. Исхак мәсәлләре, күп очракта, тәрҗемә әсәрләре. Әхмәт Исхакның иң уңышлы тәрҗемәләре – Крылов белән Михалков мәсәлләредер. Исхак–сатирик бередә үз стихиясендә. Аның сүзләр белән виртуозларча эш итүе, рифмаларның табигый яңгырашы, күтәрелгән проблемаларның татар укучысына да үз булуы мәсәлләрнең татарчага тәрҗемәләрен иң югары сәнгать әсәре дәрәҗәсенә җиткерә. Укыганда аларның тәрҗемә булулары да сизелми.

Ул - җитмеш елга якын актив иҗат гомерендә зур әдәби мирас калдырган каләм осталарының берсе. Үзе исән чагында аның кырыклап китабы дөнья күрә. Бу китапларда шагыйрьнең шигырьләре, поэмалары, сатирик һәм юмористик әсәрләре, мәсәлләре, балаларга атап язылган әкиятләре, опера либреттолары, Габдулла Тукай һәм Муса Җәлилнең поэтик осталыгын тикшерүгә багышланган әдәби-гыйльми хезмәтләре һәм башка төр әдәби язмалары тупланган. Әдипнең рус классик шагыйрьләреннән, Шәрекъ һәм төрки халыклар поэзиясеннән башкарган тәрҗемәләре генә дә, күләм ягыннан санаганда, йөз мең юлдан артып китә.

Мәсәлләрендә Ә.Исхак бюрократлардан, ялагайлардан, ялкаулардан, икейөзле кешеләрдән көлә, тормышта очрый торган башка төрле җитешсезлекләрне тәнкыйтьли. Мәсәлләрнең, шигъри фельетоннарның һәм сатирик шигырьләренең тормышчанлык көче шуның белән аңлатыла да. Бу өлкәдә үзен искеткеч бер оста итеп танытты (“Куян-редактор”, “Эшлекле әтәч”, “Карт имән белән яшь егет”, “Комсыз эт”) .

Әхмәт Исхак иҗатында балалар өчен язган әсәрләр аерым урын ала. Ул гади һәм мавыктыргыч итеп, кыланмый, арзанлы үгет-нәсихәт сатмыйча яза. Шуңа да аның әсәрләрен балалар яратып укыйлар.

Татар язучыларына, әлбәттә, рус язучысы И.Крыловның иҗаты, мәсәлләре тәэсир итмичә калмаган. Башта Крыловның мәсәлләрен татарчага тәрҗемә иткәннәр, аның сюжетын

кулланып та иҗат иткәннәр. Ә инде тора-бара яңа образлар,  яңа эчтәлекләр белән үз мәсәлләрен язганнар.

Бөек татар шагыйре Габдулла Тукай иҗатының зурлыгы аның шигъри әсәрләрендә, тәнкыйть һәм әдәбиятка, тарихка караган гыйльми хезмәтләрендә дә чагыла.Ул барлык алга киткән милләтләрдән үрнәк алырга, аларның тәҗрибәсен өйрәнергә чакыра. Ә тәрҗемәне ул алдынгы әдәбиятларны татар халкына җиткерүнең төп чарасы дип саный.

Башка әдәбиятлардан ул сүз сәнгатенең асылы, аның үзенчәлекләре, сурәтләү чаралары, тормышка һәм чынбарлыкка мөнәсәбәте кебек сыйфатларын өйрәнә. Шагыйрь үз хезмәтләрен тәрҗемә итүнең сыйфатын яхшыртуга багышлый. Ул ирекле тәрҗемәне яклап чыга. „Русчадан дөрес тәрҗемәләр” дигән хезмәтендә ул сүзгә - сүз тәрҗемәнең ямьсез нәтиҗәләр китерүен күрсәтә. Шулай ук теге яки бу телдән тәрҗемә иткәндә , шул халыкның гореф – гадәтләрен, традицияләрен искә алырга чакыра. Тәрҗемәченең телне яхшы белүен төп шарт итеп куя.

Тукайның беренче тәрҗемәләре – Крылов мәсәлләре – 1906-1907 елларда “Әлгасрелҗәдит” журналында басыла. Габдулла Крыловның 75 мәсәлен тәрҗемә итә. Шагыйрь тәрҗемәләренең күпчелеге патриотик хисләрне чагылдыралар (“Бүре Этләр арасында”), горур рухка дан җырлыйлар (“Тавыклар һәм Каракош”), хезмәт халкына мәхәббәт белдерәләр. Кайбер мәсәлләрне татарчада башка исем белән биргән ул: “Синица” – “Бытбылдык”; “Волк и Лисица”- “Юмарт дус”.

Тукай мәсәлләрне тәрҗемә иткәндә, оригиналларның эчтәлеген өстән генә сөйләп чыгуга кайтарып калдырмый, аларның социаль һәм сатирик мәгънәсен тирән төшенеп эш итә. Мәсәлән, “Бүре Этләр арасында” мәсәленең эчтәлегенә, рухына тапкыр килгән мораль чыгара (“Адәм баласы җиңелгән заманында солых яратучан буладыр”).

Аерым мәсәлләрдә Тукай үз нәтиҗәсен ясый, һәм бу нәтиҗә сатирик характеры белән аерылып тора. Мәсәлән, Тукай “Тиен” мәсәлен татар шәкертләренең тормышын һәм укуларын тәнкыйтьли торган юллар белән тәмамлый.

Күренгәнчә, Крылов сатирасы Тукайга көчле йогынты ясаган. Аны Крылов сатирасының реалистик көче һәм халыкчанлыгы үзенә тарта. Тукай тәрҗемәләре элеккеге тәрҗемәләрдән оригинал үзенчәлекләрен саклап калулары, оригиналның тел һәм художество элементларын детальләштереп бирүләре белән аерылып торалар. Шуңа күрә Тукай мәсәлләрендә татар халык сөйләменең байлыгы да киңрәк һәм тирәнрәк гәүдәләнә.

Уральскида 1906-1907 нче елларда „Файдалы җыентык” исеме астында Тукайның проза белән язылган 76 мәсәле басыла. Җыентыкның титул битендә , “Зирәк һәм таныклы рус язучысы Крыловның кызыклы әсәрләреннән ирекле рәвештә тәрҗемә ителде. Габдулла Тукаев”,- дип язылган [23,б.243]. Үз вакытында И.Крыловның мәсәлләрен дә файдаланып, ул соңыннан 1909 нчы елда ул 70 мәсәлне бераз редакцияләп, телен җиңеләйтеп, яңадан мәсәлләр өстәп, барлыгы 77 мәсәлне эченә алган “Энҗе бөртекләре” исемле җыентык чыгара . Г.Тукайның прозасы кыска күләмле, бай һәм үтемле булуы белән игътибарны җәлеп итә, аның чәчмә әсәрләренә халык мәкальләрендәгечә тирән акыл, тапкырлык хас. Атап әйткәндә, “Аю мәҗлесе”, “Мактанчык куян”, “Чүлмәк илә казан”, “Чабак”, “Ташбака илә куян”, “Ике күгәрчен” һ.б. хикәят- мәсәлләрен укып балалар күпьяклы тәрбия һәм тәҗрибә алалар.

Хезмәтебездә Г. Тукай һәм И. А. Крылов мәсәлләрен чагыштырып карарга булдык. Бу мәсәлләр шагыйрьнең гаҗәеп дәрәҗәдә оста тәрҗемәче булуын күрсәтә, алар –ирекле тәрҗемә әсәрләре.

Мәсәлән,

“Арыслан илә тычкан” әсәре Крыловның “Лев и мышь” дигән мәсәленнән.

Крылов үз мәсәлен:

Читатель, истину любя,
Примолвлю в басне я, и то не от себя:
Не попусту в народе говорится:
Не плюй в колодезь- пригодится
Воды напиться.

дигән юллар белән тәмамлый.

Бу мәсәлдә Тукай үзе еш кулланган халык әйтемен “Коега төкермә, бервакыт су эчәргә кирәк булыр” дип өстәгән.

“Аю” әсәре “Медведь в сетях” мәсәленнән.

Крылов мәсәле:

Так лучше бы ты мертвых ел,
И оставлял живых в покое

дигән сүзләр белән бетә.

“Аюларның үлгән кешеләрне ашамаганлыклары мәгълүм” дигән нәтиҗәне Тукай үзе өстәп куйган.

“Аю мәҗлесе” –Крыловның “Обед у Медведя” дигән мәсәленнән тәрҗемә.

Шагыйрь:

“Ары да барып биисең, бире дә килеп биисең,
Бигрәк тә оста биисең, күз тияр дип белмисең”,

дигән икеюллык халык җырын кертеп куйган. Ул безнең җырны бик урынлы кулланган.

“Бәти” мәсәле Крыловның “Ягненок” әсәре тәрҗемәсе.

Крылов мәсәле:

А если бы ягненок был умен,
И мысли бы боялся он
Похожим быть на волка.

Тукай мәсәлгә:

Явызларга тыштан гына булса да охшарга ярамый дигән нәсихәтне өстәгән.

“Бүре илә тычкан” әсәре “Волк и Мышонок” мәсәленнән.

Крылов үз әсәрен:

Такое же в городе я видел приключенье:
У Климыча - судьи часишки вор стянул,
И он кричит на вора: караул!- дип тәмамлана.

Тукай: “Дустлар! Бүре бу малны үзе кайдан алган иде?”- дигән сорау белән тәмамлаган. Үз соравы белән шагыйрь безне уйланырга, сорауга җавап эзләргә өнди.

“Бытбылдык”- Крыловның „Синица” дигән мәсәленнән.

Крылов: Примолвить к речи здесь годится
Но ничего не трогая лица,
Что делом, не сведя конца,
Не надобно хвалиться

Әдип мәсәлгә:

“Бу урында һичкемнең йөзен ертмыйча гына бер сүз әйтергә мөмкин:

Бер эшнең очына чыкмыйча мактану кирәкмәс” - дип өстәгән. Мактану сыйфаты әдәпсез кешеләргә хас.

“Җылан”- „Змея” исемле мәсәл тәрҗемәсе.

Крыловта нәтиҗә-нәсихәт өстәлмәгән**.**

Нәтиҗә- нәсихәтне Тукай үзе өстәгән:

Ах, дустлар! Әгәр дә шигырь саф күңелле кешенең агызыннан чыкса, йөрәкләрне өзәдер. Әмма җылан шикелле агулы кеше агызыннан чыкса, аның агуы шигырьнең күркәмлеген каплыйдыр.

“Ике күгәрчен” әсәре Крыловның “Два Голубя” исемле мәсәле тәрҗемәсе.

Крылов яза:

Что б ни сулило вам воображенье ваше;
Но, верьте , той земли не сыщете вы краше,
Где ваша милая иль где живет ваш друг.

Тукай нәтиҗә өлешенә:

Әй, сез, бөтен дөньяны сәяхәт итәргә теләүчеләр! Сез кайда барсагыз да, үзегез туып-үскән җирдән сөекле һәм дусларыгыз торган җирдән матур җир таба алмассыз,-

дип язган.

“Картайган арыслан” – “Лев состарившийся” мәсәленнән.

Крылов нәтиҗәне өстәмәгән.

Тукай:

Үзеңнең барачак юлыңа таш атма. Яшь вакытта ни чәчсәң,шуны картайгач урмыйча, кабергә кермәссең,-

дип язган.

“Мәче илә сандугач” – “Кошка и Соловей” мәсәле тәрҗемәсе. Крыловта түбәндәге нәтиҗә бар:

Сказать ли на ушко яснее мысль мою?
Худые песни Соловью
В когтях у Кошки.

Тукай моны: “Дустлар! Уйлап карыйк әле: мәче тырнагында сандугач сайрармы?”- дип бирә.

“Мәче баласы һәм сыерчык”- “Котенок и Скворец” исемле мәсәлендә Крылов нәсихәт өстәмәгән.

Тукай: Бераү кардәшенә кое казыса, үзе төшәр- дип үзе яраткан мәкален өстәгән.

“Тәүбә иткән төлке” – “Крестьянин и лисица” мәсәле тәрҗемәсе.

Крылов мәсәлендә:

В ком есть и совесть, и закон,
Тот не украдет, не обманет,
В какой бы нужде ни был он;
А вору дай хоть миллион –
Он воровать не перестанет.

Тукай мәсәлендә*:*

Намусы, ояты булган кеше нинди тарлыкка төшсә дә – урламас; әмма каракка миллион тәңкә бирсәң дә, урлаудан туктамас.

“Күке илә күгәрчен” – “Кукушка и горлинка” мәсәленең тәрҗемәсе.

Крылов:

Отцы и матери! Вам басни сей урок.
Я рассказал ее не детям в извиненье:
К родителям в них непочтенье
И нелюбовь- всегда порок;
Но если выросли они в разлуке с вами
И вы их вверили наемничьим рукам-
Не вы ли виноваты сами,
Что в старости от них утехи мало вам?

Тукай:

“Аталар! Аналар! Бу сезгә сабак. Мин моны балаларны гаепләр өчен язмадым. Балаларыңыз сездән аерылып, кеше кулында үссәләр, кечкенә вакытта сездән хөрмәт күреп, сезнең тарафтан сөелми үссәләр, карт көнегездә сезгә әйләнеп тә карамаслар”, - дип тәрҗемә иткән.

Әсәрләр кыска күләмле, фикергә бай булуы белән аерылып тора. Алар сүзгә- сүз тәрҗемә түгел, татарлар тормышына җайлаштырылып үзгәртелгән. Тукай үз халкын зирәк, акыллы, уңган, көчле, кыю, тапкыр итеп күрергә тели һәм хыялны үзенең мәсәлләрендә персонажлар вазифасын башкаручы кош-кортлар, хайваннар, кешеләр аша күрсәтә. Тукайның исеме, иҗаты һәм мирасы да онытылырга тиеш түгел.

Мәсәлләрнең килеп чыгышы ерак гасырларга килеп тоташуын һәм күп кенә шәхесләребезнең рус теленнән мәсәлләрне тәрҗемә итеп, үзләре дә иҗат итә башлаулары беленде. И.Крылов һәм Г.Тукайның мәсәлләрен чагыштырып өйрәнгәннән соң, Г.Тукайның

прозасы кыска күләмле, бай һәм үтемле булуы белән игътибарны җәлеп итүе, мәсәлләрендә татар халык сөйләменең байлыгы да киңрәк һәм тирәнрәк гәүдәләнүе ачыкланды. Ләкин бүгенге көндә мәсәл иҗат итүче шәхесләр юк. Бу- әлбәттә, кызганыч.

Мәсәлләрнең халык авыз иҗатыннан мәкаль һәм әйтемнәр белән тыгыз бәйләнештә торуы да күренде. Тагын мәсәлләрнең үзенчәлекле ягы шунда: һәр мәсәлдә мораль ята. Ул мәсәлнең башында, я азагында килергә, яки җинел аңлашыла икән, булмавы да мөмкин.

Бу кыйммәтле хәзинәләрнең тарихи һәм тәрбияви әһәмияте елдан-ел үсә. Һәрберсендә мораль яткан мәсәлләрне уку бик тә кирәк. Чөнки нинди дә булса акыл, гыйбрәткә бай булуы белән бу әсәр балаларны тормышка әзерли. Аларның нигезендә кешелеклелек, тыйнаклык, гаделлек, дуслык, әдәплелек, бер-береңне ихтирам итү, мәрхәмәтлелек, олыларга хөрмәт, шәфкатьлелек кебек бик матур сыйфатлар ятуы беленде.

Әдәбият фәне - халкыбызның әхлак кагыйдәләрен, рухи мирасын киләчәк буыннарга тапшыру чарасы. Туган телгә, әдәбиятка өйрәтүче мөгаллим исә- балага шушы хакыйкатьне аңлатучы, төшендерүче сүз аһәңен балага җиткерүче.

Әдәбият дәресләрендә укытучының максаты- халкыбызның мәдәниятен, гореф-гадәтләрен, иң күркәм йолаларын, тарихын хөрмәт итәргә өйрәтү.

Укучыларны тәрбияләүдә мәсәлнең потенциалы зур. Аның эчтәлеге мөһим әхлак проблемаларын һәм аларны чишү буенча акыллы киңәшләр бирүне күздә тота. Мәсәлнең аңлаешлыгы аның характерлы жанр үзенчәлекләренә кайтып кала: образлылык, сөйләм сәнгатьлелеге, хикәяләүнең кыскалыгы, таныш геройлар, оста сюжет сызыгы, мәсәл кинаясе. Мәсәлдә баланың хисле эчке дөньясына тәэсир итә торган бай материал тупланган. Алар укучыларда әдәби сүзнең югары мораль сыйфатларын тәрбияли. Яңа федераль стандартларга нигезләнеп төзелгән дәреслекләрдә дә мәсәлләр турында мәгълүматлар һәм аның үрнәкләре бирелгән. Мәсәлләрнең нигезендә кешелеклелек, тыйнаклык, гаделлек, дуслык, әдәплелек, бер-береңне ихтирам итү, мәрхәмәтлелек, олыларга хөрмәт, шәфкатьлелек кебек бик матур сыйфатлар ята.

Алда куелган бурычлардан чыгып, түбәндәге нәтиҗәләргә килende:

*Беренчедән,* мәсәлләрнең килеп чыгышы ерак гасырларга килеп тоташуын һәм мәсәлләрне язучылар, шагыйрьләрнең башка телдән тәрҗемә итеп, үзләре дә мәсәл иҗат итүгә кереп китүләрен белдек. Ләкин бүгенге көндә мәсәл иҗат итүче шәхесләребез юк. Бу- әлбәттә, кызганыч.

*Икенчедән,* һәр мәсәл нинди дә булса тәрбияви әһәмияткә ия. Балаларда туган илгә мәхәббәт, белем алуга омтылыш, иптәшлек, намуслылык, ихтыяр көче, әдәплелек, туганлык кебек күркәм сыйфатлар тәрбияләү- башлангыч мәктәп алдында торган иң мөһим бурычларның берсе.

*Өченчедән,* бу кыйммәтле хәзинәләрнең тарихи һәм тәрбияви әһәмияте елдан-ел үсә. Һәрберсендә мораль яткан мәсәлләрне уку бик тә кирәк. Башлангыч сыйныф укучыларын мәсәлгә өйрәтү методикасында бүгенге көнгә кадәр үзгәрешләр юк дип әйтергә була. Уку эшчәнлегендә мәсәл дидактик әсәр жанры буларак өйрәнелүне дәвам итә. Нинди дә булса акыл, гыйбрәткә бай булуы белән бу әсәр балаларны тормышка әзерли дип әйтә алабыз.

Яшь буын шушы сыйфатларга ия булса гына киләчәгебез якты булачак. Ә бу сыйфатларны тәрбияләү, һичшиксез, укытучыларның олы бурычы. Гомумән, мәсәлләр – зур акыллылык, сәламәт әхлаклылык чишмәсе.

*Кулланылган әдәбият исемлеге:*


1. Александров И.Б. Иван Андреевич Крылов – баснописец. Русская речь. – 2004.- 136 с.
2. Әхмәдуллин А. Әдәбият белеме сүзлеге/ А.Әхмәдуллин. - Казан: "Мәгариф-Вакыт" нәшр., 1995.-237 б.
3. Вагыйзов С.Г. Башлангыч мәктәптә татар теле методикасы/ С.Г.Вагыйзов, Р.Г. Вәлитова, Казан: Мәгариф, 2001.-344 б.
4. Вагыйзов С.Г. Уку китабы: Дүртьеллык башл. татар мәкт. 2нче с-фы өчен д-лек/ С.Г.Вагыйзов, Р.Г. Вәлитова, Р.И.Раскулова.- Казан: Мәгариф, 2002.-183 б.

5. Виноградов В.В. Язык и стиль басен Крылова. Языковая природа афоризма. - Могилев, 2001. – 233 с.
6. Воропаева В.С., Куцанова Т.С. Особенности изучения басен / В.С.Воропаева ,Т.С. Куцанова .– Казань :1980. – 267 с.
7. Газизов Р. Габдулла Тукай. Мәктәп укучысына ярдәмлек. Казан , 2001 ел.-365 б.
8. Галиуллин Т. Илһам чишмәләре. Традицияләр яшәрә/ Т.Галиуллин.- Казан: Татар. кит. нәшр., 1988.-361 б.
9. Гарифуллина Ф.Ш. Әдәби уку: рус телендә башл. гомуми белем бирү мәкт. 3нче с-фы өчен д-лек(татар балалары өчен) 1нче кисәк /Ф.Ш.Гарифуллина, И.Х.Мияссарова; [рәссамы Л.Золондинова] .-Казан: “Мәгариф-Вакыт” нәшр., 2013.-128 б.
10. Гаффарова Ф.Ф. Татар теленең мәктәпләр өчен аңлатмалы сүзлеге./ Гаффарова Ф.Ф., Ганиев Ф.А., Саберова Г.Г. (редк.). – К.: Татар.кит.нәшр., 2013. – 510 б.
11. Гафури М. Сайланма әсәрләр.-Казан: Татарстан Республикасы “Хәтер” нәшрияты, 2007.- 479 б.
12. Жуковский В.А. О басне и баснях Крылова. В кн: «И.А. Крылов. Басни. Комедии. Повесть» - М., 2000. – 245 с.
13. Заһидуллина Д.Ф. Әдәби әсәргә анализ ясау / Д.Ф.Заһидуллина, В.Р. Әминев, Ибраһимов М.И.– Казан: Мәгариф, 2005. – 110 б.
14. Заһидуллина Д.Ф./ Татар әдәбияты: Теория. Тарих./Д.Ф.Заһидуллина, Ә.М.Закирҗанов, Т.Ш.Гыйләҗев.-Казан: Мәгариф, 2004.-248 б.
15. Исәнбәт Н. Балалар дөньясы: Такмак-такмазалар, җыр, мәкаль, табышмаклар, алдавыч әкиятләр һәм башкалар. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1970. –320 б.
16. Исәнбәт Н. Балалар фольклоры һәм җырлы-сүзле йөз төрле уен .Төз..Казан: Тат.кит.нәшр., 1984. – 45 б.
17. Крылов И.А. Мәсәлләр/ И.А.Крылов.-Казан: Татар.кит.нәшр., 1992.- 298 б.
18. Минһаҗева Л.И., Мияссарова И.Х. Татар балалар әдәбияты “Хәтер” нәшрияты. Казан: 2009.-180 б.
19. Мусин Ф. Татар әдәбияты: рус урта гомуми белем мәктәпләренең 7 нче сыйныфта укучы татар балалары өчен дәреслек/Ф.Мусин, И.Г.Гыйләҗев, Р.Шәвәлиева.- Казан: Мәгариф, 1999. – 56 б.
20. Сафиуллина Г. Әдәби уку: татар телендә башл. гомуми белем бирү мәкт. 3нче с-фы өчен д-лек. 2 нче кисәк/Г.М.Сафиуллина, Ф.Ф.Хәсәнова, Ә.Г.Мөхәмәтҗанова: рәссамы Ф.Ризаева.-Казан: “Мәгариф-Вакыт” нәшр., 2013.-119 б.
21. Сафиуллина Г.М. Әдәби уку: татар телендә башл. гомуми белем бирү мәкт. 3нче с-фы өчен д-лек-хрестоматия. 3нче кисәк/Г.М.Сафиуллина, Ф.Ф.Хәсәнова, Ә.Г.Мөхәмәтҗанова: рәссамы Ф.Ризаева.-Казан: “Мәгариф-Вакыт” нәшр., 2013.-111 б.
22. Сафиуллина Г.М. әдәби уку: татар телендә башл. гомуми белем бирү мәкт. 3нче с-фы өчен мөстәкыйль эш дәфтәре/Г.М.Сафиуллина, Ф.Ф.Хәсәнова, Ә.Г.Мөхәмәтҗанова: рәссамы Ф.Ризаева.-Казан: “Мәгариф-Вакыт” нәшр., 2013.-111 б.
23. Тукай Г. Әсәрләр. Биш томда. Казан: Тат.кит.нәшр., 1986. - 368 б.
24. Тукай Г. Сайланма әсәрләр: шигырьләр, поэмалар һәм чәчмә әсәрләр/ Г.Тукай; төз., кереш сүз авт. Ф.Бәшәр.-Казан: Татар.кит.нәшр., 2003.-479 б.
25. Шамуков А.Р. Мәсәлләр. Казан: Тат.кит.нәшр., 1969. – 135 б.
26. Шәймәрданов Р.Х., Хуҗиәхмәтов Ә.Н.. Татар милли педагогикасы. Казан, “Мәгариф” нәшрияты, 2007.-223 б.
27. Ягъфәров Р. Балалар фольклоры / Татар халык иҗаты // Балалар фольклоры. – Казан, Татар. кит. нәшр., 1993. – 217 б.
28. Ягъфәрова Р.Х. Уку китабы: Дүртьеллык башл. татар мәкт. 4нче с-фы өчен д-лек:2кисәктә.1нче кисәк / Р.Х.Ягъфәрова.-Казан: Мәгариф, 2004.-142 б.
29. Яхин А.Г әдәбият: Дүртьеллык башл.татар мәкт. 2нче с-фы өчен дәреслек-хрестоматия/ А.Г.Яхин.-Тулыл. 2нче басма.-Казан: Мәгариф, 2003.-159 б.

30. Яхин А.Г. әдәбият: Дүртьеллык башл.татар мәкт. 1нче с-фы өчен д-лек/ А.Г.Яхин.- Тулыл. 2нче басма.-Казан: Мәгариф, 2009.-119 б.
*Интернет ресурслар*
37.http://tazbash.ru/halyk-ijaty/uennar/160-bala-uennar
38.Википедия сайты. https: //tt.wikipedia.org/wiki

## АМУР ФӘЛӘХНЕҢ “ТАШ БӘГЫРЬ” ӘСӘРЕНДӘ НАРКОМАНИЯ МӘСЬӘЛӘСЕНЕҢ ЧАГЫЛЫШЫ

*Хакова Лилия Радик кызы, Кукмара 3 нче урта мәктәбенең 11 нче сыйныф укучысы*
*Фәнни җитәкче: Хәсәнова Гүзәлия Габделнур кызы, Кукмара 3нче урта мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучылары*

Китапханәгә кергәч, китаплар киштәсендә минем күземә Амур Фәләхнең “Таш бәгырь” исемле әсәрләр җыентыгы чалынды. Бу китап авторның беренче җыентыгы булуы мине кызыксындырды. Беренче әсәрен укуга ук, мине А.Фәләхнең бүгенге заманда тирән тамыр җәйгән тискәре күренешләрне әсәрендә күтәреп, тәнкыйтьләп язуы шаккатырды. Мин хезмәтемне Амур Фәләхнең “Таш бәгырь” әсәре буенча язарга булдым.

А.Фәләх турында мәгълүматлар табу шактый кыен булды. Аның мәкаләләре журналларда даими рәвештә күренсәләр дә, А.Фәләхнең шәхси тормышына багышланган мәкаләләр аз.

1965 нче елда Мамадыш районы Яңа Комазан авылында туган Амур Казан дәүләт университетында бераз укып алгач, Ижауда “Яңарыш” газетасының баш мөхәррире сыйфатында, бераз гына Удмуртия татарларының милли хәрәкәтен әйдәкләүчеләр сафында булган.

Финанс кытлыгы нәтиҗәсендә “Аргамак” ябылгач, Амур Фәләх төрле эшләрдә эшләп ала. Ниһаять, Чаллы хакимиятенең фатихасы белән , “Мәйдан” журналы дөньяга тугач, яшь каләм остасы үзенә лаеклы иҗат оясы таба. Укучыга бер-бер артлы кызыклы, мәгънәле әсәрләр тәкъдим итәргә керешә. Аның әсәрләре “Мәйдан” журналында гына түгел, “Мәдәни җомга”, “Ватаным Татарстан” кебек үзәк газеталарда да басыла *[4]*. Амур Фәләх бүгенге көндә “Мәйдан” журналында эшли.

Рәшит Бәшәр үзенең “Язучының күңел дөньясы” исемле мәкаләсендә: “Меньеллык тарихы булган татар әдәбиятына Амур Фәләх исемле өр-яңа язучы килә*”,[1]-* ди. Шулай ук язучының башлангычын хуплап Вахит Имамов “Таныш булыгыз: Амур Фәләх” дигән мәкаләсендә “ . . . яшь каләмдәшебез колагына бер генә сүз: афәрин, Амур туган!“ *[1]-* дип яза. Мәкаләләрдә А.Фәләх турында мондый фикерләр уку, аңа шундый теләкләр теләүләрен белү, бездә ул алга таба танылган бөек язучы булыр дигән өмет уята.

А.Фәләхнең “Таш бәгырь” повестенда хәзерге көндә Россиядә иң зур афәт- яшь буынның өчтән бер өлеше кереп баткан наркомания атлы төпсез сазлык мәсьәләсе күтәрелгән. Бу тема хәзерге вакытта бик актуаль. Газета- журналларда, телевидениядә бу мәсьәләгә багышланган тапшырулар, мәкаләләр бик күп. Әледән әле мәктәпләрдә наркомания афәтенә багышланган лекцияләр, атналыклар булып тора. Шуларны истә тотып, мин хезмәтемне “Амур Фәләхнең “Таш бәгырь” әсәрендә наркомания мәсьәләсенең чагылышы“ дип исемләргә булдым. Бу хезмәтемдә мин үз алдыма авторның бу афәтне әсәрендә ничек яктыртуын ачыклау максатын куйдым. Максатыма ирешү өчен, мин башта наркомания турында гомуми фикер йөртеп, соңыннан бу афәтнең әсәрдә ничек күтәрелүен күзәтмәкче булам.

Гипотеза – минем фаразлавымча, кешенең наркотиклар куллана башлавына, беренче чиратта, кеше факторы роль уйный.

Фәнни-тикшеренү эшенең методикасы: эш барышында әдәби әсәр укылды, анализланды, әсәрдә күтәрелгән проблема буенча материал тупланды, сорашу үткәрелде, фактик материаллар белән баетылды, нәтиҗә ясалды.

Наркомания – организмның хроник агулану халәте, кешенең наркотикка тартылуны җиңә алмаслык дәрәҗәгә җитүе.*[3]* Моны һәркем белә, ләкин шуңа да карамастан, наркотиклар кулланучыларның саны көннән көн арта. Шунысы аянычлы: наркотиклар кулланучыларның күпчелеге – яшьләр һәм наркоманнарның яше ел саен яшәрә баралар. Шуның өчен бала беренче мәгълүматны гаиләдә алырга тиеш. Ата-аналар бу турыда башлангыч мәгълүматны белергә тиеш.

“Совет власте елларында наркомания турында ишетеп кенә белә идек. Бу афәттән социализм чорында ил җитәкчеләре дә сакландылар. Яшьләр арасында бу афәт таралмасын дип күзәтчелек тә бик көчле иде. Ул заманнарда бу чирнең бик куркыныч икәнен аңлаганнар”, - дип сөйләде безгә укытучыбыз М. Мәликованың “Чәчкә балы” дигән әсәрен укыгач.

90-нчы елларда демократия җилләре искәч, бу давыл безгә дә килеп җитә. Әкрен генә яшьләрне үзенә йота башлый. Илебездә яшьләрне кыра торган “дошман” барлыкка килә. Дошманның көчәйгән басымы белән нәтиҗәле көрәшү өчен аның турында күбрәк белергә кирәк, дигән бер акыл иясе. Күренми торган, әмма бик тә куркыныч булган дошман-наркомания белән нәтиҗәлерәк көрәшү өчен дә шушы стратегияне кулланы дөрес булыр, мөгаен. Билгеле, хакыйкать теләсә кайсы хәрәкәт, хәлне дөрес белмәүдән башлана.

Бүгенге көндә һәр ата-ана, барлык укытучылар балаларда наркоманиягә каршы нәфрәт хисе тудырырга тырыша.

Татарстан мәктәпләрендә укучыларга анкета биреп, укучыларның наркоманиягә булган мөнәсәбәтләрен өйрәнәләр.

Нәтиҗәләр болайрак :

10 класс укучылары арасында үткәрелгән анкета нәтиҗәләренә күз салсак, шуны күрәбез: аларның 90 проценты тәмәке пыскыта, 95 проценты спиртлы эчемлекләр белән таныша, ә 60 проценты хәтта наркотикларны да кулланып караган инде. Бары тик 30 проценты гына сәламәт яшәү рәвешен хуплый.*[4]*

Безнең тарафтан, мәктәбебездә наркоманлыкка китерүнең сәбәпләрен ачыклау максатыннан, сорашу үткәрелде. Моның белән генә тукталасы килмичә, районыбыз яшьләре арасында эчүчелекнең, наркоманлыкның таралуын белү максаты белән, Кукмара эчке эшләр бүлегенә мөрәҗәгать иттек. Андагы мәгълүматлар безне уйланырга мәҗбүр итте:

2015 елда 31кеше;

2016 елда 41 кеше;

2017 елда 48 кеше исәптә тора.

Кукмара эчке эшләр бүлеге җитәкчесе Р. Нургалиев Балтач районында 1 наркоман гына булуын гына искәртте. Наркоманнарның районда күп булуын ул Кукмара районы аша тимер юл, автотрассалар үтү, промышленностьның үсүе белән бәйләп аңлата.

“Таш бәгырь” әсәрендә наркомания мәсьәләсе бик ачык күтәрелгән. Монда наркоманнарның наркотикларны куллана башлауларыннан үлемнәренә кадәрге тормышлары сурәтләнгән. Бу - наркоманның тормыш әсбабы булырдай әсәр.

Автор наркомания мәсьәләсенә тирәнрәк керү, төшенү максаты белән бу дөньяның төрле катламнарын сурәтли. Әсәрдә наркотикларны сатучылар да, кулланучылар да, наркоманнарның туганнары да күрсәтелә. Безгә авторның наркоманиягә карата фикерен, бу мәсьәләне ничек күзаллавын белер өчен, бу өч катламның берәр вәкилен генә булса да аерым алып карарга кирәк булачак.

Без карыйсы геройларның беренчесе булып, төп герой Әмирнең бертуган энесе - Хәмит тора. Ул- наркоман, ләкин башка бик күпләр кебек Хәмит бу юлга үзе теләп басмаган, аны мәҗбүр иткәннәр.

Хәмит үрнәк, тулы гаиләдән. Мәктәптә ул гел яхшы билгеләренә укыган. Элегрәк наркоманнарны күргәндә, аның ачуы кабара торган булган. Ләкин бер көнне бу унынчы

сыйныфта укучы егетне классташы, әҗәткә илле сум сорап, кәеф күтәрү максаты белән, кибет подвалына алып төшә. Монда алар наркотиклар сатучы егетләрне очраталар. Бу егетләр Хәмиткә наркотик тәкъдим итәләр, ә аның: "Беләм мин бу нәрсәне. Миңа кирәге юк аның*,"[1]* – дигәнен ишеткәч, көчләп наркотик кадыйлар. Бу кадаулар берничә мәртәбә кабатлана. Шулай итеп, Хәмит чын наркоманга әверелә. Баштагы мәлдә ата-анасыннан вак-төяккә дип, акча сорап, наркотиклар ала, соңыннан видеокасеталарын, музыкаль үзәген сата. Шуны әйтергә кирәк, А.Фәләхнең бу образы реаль тормышка якын итеп сурәтләнгән. Хәзерге көндә көчләп инәгә утыртылган кешеләр бик күп.

Хәмитнең бөтен хәрәкәтендә, эш-гамәлләрендә сүлпәнлек, көчсезлек күренә. Ул бу сазлыктан чыгарга тели. Моның өчен аңа ярдәм итүче, юл күрсәтүче ышанычлы кеше кирәк. Хәмит кешеләрдән ярдәм өмет итә. Наркотикларны ташлау өчен наркодиспансерга мөрәҗәгать итә. Язучы диспансердагы мөгамәләне Хәмит теле белән әйтә: " Анда минем ишене кешегә дә санамыйлар." *[1]* Ә бу бит наркоманнарга наркотиклардан арынуга ярдәм итәр өчен оештырылган махсус оешма. Наркодиспансерда наркоманнарга мондый мөгаләмәдә булулары башка сыймый. Чынлыкта исә, бу - язучы тарафыннан ассызлыкланган реаль чынбарлык. Хәмит наркодиспансерда да үзен аңлаучы булмагач, терелүгә өметен өзә. "Бераздан бармый башладым, ышанычым бетте", *[1]* - ди.

Әмир энесенә ярдәм кулы сузарга әзер, аның Хәмитне бу упкыннан йолып алырдай көче бар. Әйе, Хәмитнең үзенә дә бик күп көч сарыф итәргә кирәк булачак, ләкин ярдәм итәрдәй кеше булуы көрәшү өчен көч өсти. Һәм менә караңгылыкта яктылык күренә башлагач, Хәмит терелер дигән өмет барлыкка килгәч кенә, А.Фәләх вакыйгаларны кирегә бора да куя. Хәмиткә көчләп, күп итеп наркотик дозасы кадыйлар да, ул "передозировка"дан үлә. Бәлки, автор бу гамәле белән наркотикларның һәлакәткә китерүен аныграк, үтемлерәк күрсәтергә телидер.

Әсәрдә тагын бер наркоман бар, ул да булса Юра. Аның бу юлга ничек килеп керүе безгә хәбәр ителми. Юра – ахыргы чиккә җиткән наркоман. Аның кичерешләрен А.Фәтих бик җентекләп сурәтли. Юра шундый дәрәҗәгә җиткән ки, аның өендә алып сатар өчен әйбере юк. "Фатир буп-буш : чыгарып сатарлык бер генә җиһаз да күренми." *[1]*

Юра өчен бу доза дөньяда иң кыйммәтле, иң кирәкле әйбер. Аның нинди халәттә булуын автор менә ничек сурәтли :"Бер доза әфьюн өчен җанын сатарга да әзер иде ул бу мизгелдә."*[1]*Тормышта да шундый була, наркоманнар кеше үтерүдән дә, талаудан да тартынып тормыйлар.

А.Фәләх наркоманнарның психик халәте генә түгел, ә физик халәте дә авыр булуын күрсәтә "... чигәләре чүкеч белән суккандагыдай авырта, эчәкләре нindидер корт кимергәндәй ялкынсына, тәне токка тыккандай туктаусыз дерелди... "*[1]* – дип яза.

Юраның психикасы шулкадәр какшаган ки, аның күзенә күренә башлый. Ул үзенең өстендә төрле бөҗәкләр чабуын күрә, ә аларның хыялда гына булуларын белгәч гарьләнә.

Юра үзенең хәлен җиңеләйтер өчен кан тамырларын кисеп, ваннага су тутырып ята һәм рәхәтлек тоя башлый. Инде бөтенләй йокыга киткәндә ул сикереп торып тизрәк кулын бәйли. Язучының героен шундый ситуациягә куюы очраклы түгел. Монда без Юраның нинди сазлыкта булуына карамастан, яшәргә теләвен күрәбез. Автор моны ассызыклап китә: " Киселгән тамырлардан каны агып бетәр дә, хастаханәгә барып җитә алмам дип курыкты Юра. Кайдадыр, күңеленең ерак кына бер почмагында нindидер өмет, яшәү теләге уянды ... "*[1]* Димәк, наркоманнарның наркотикларны куллану стажлары нинди булуына карамастан, яшәргә теләкләре, терелергә өметләре югалмый.

Юра киләчәккә өмет белән карый, якты киләчәккә ышана:" ... Мин дә терелермен, башкалар кебек тиргә батып эшләрмен, көрәп акча алырмын, типтереп яшәрмен әле... "*[1]* дип уйлый ул. Әйе, Юраның моңа хакы бар, тик ул бу киләчәкне якынайтыр өчен бернәрсә дә эшләми. Хәтта, киресенчә, наркотиклар куллануны дәвам итеп, гомерен куркыныч астына куя.

Наркомания дөньясының икенче төркем вәкиле-Газинур. Ул наркоманнар, аларның туганнары хәсрәтендә акча эшләп, бай, мул тормышта яшәүче кеше. Газинур –

наркомафиянең бер вәкиле. Аның тормыш юлын сурәтләүгә Амур Фәләх аеруча зур игътибар иткән.

Газинур үрнәк гаиләдә тәрбияләнеп үскән, спорт түгәрәгенә йөргән. Дүртенче сыйныфта укыганда каратэ белән шөгыльләнә башлаган. Россиянең төрле шәһәрләрендә узган ярышларда катнашып, унынчы сыйныфта укыганда ук кара билбау алуга ирешкән. Аның наркоманнарга карата мөнәсәбәтен дә автор күрсәтеп китә.“ Наркоманиягә бөтен җаны-тәне белән каршы егет, урамда яки башка берәр урында әфьюнчы очратса, аны канга батырып бетергәнче кыйный иде, *“[1]–* ди. Газинурның тормышы турында шундый мәгълүматлар белгәч, аның һич тә наркотиклар белән бәйләнер дип уйламассың. Ләкин тормышның ничек борылуын беркем дә тәгаен әйтә алмый. Газинур белән дә шул хәл була.

Газинур наркотик таратучылар янына барып чыга, һәм алар аны куркытып акча суырмакчы булалар. Монда да автор көтелмәгән борылыш ясый. Наркотик таратучыларның “бос”ы Борис Михалыч Газинурның әтисенең дусты булып чыга. Ул Газинурга наркотиклар белән шөгыльләнергә тәкъдим итә. Мондый егетнең бу түбән эшкә ризалашуына кем ышансын! Газинур безнең фикерне башта дәлилли һәм бу керешле бизнестан баш тарта. Ләкин тормышта андый кешеләр аз шул. Шуны исәпкә алып, язучы: “ ... ләкин нәфес дигәнең тиз генә бирешә торганнардан түгел шул: башка чарасы калмаган Газинур бераздан наркотик сатучы булып китте, “*[1]–* ди.

Газинур шулай булыр дип кем уйлаган. Ул врач, Гиппократ антын биргән кеше. Кешеләргә ярдәм итеп, наркоманнарны сазлыктан йолып алу урынында, ул наркотиклар тарата башлый.

Газинур турында хикәяләгәндә, автор наркотикларны тарату урыннарын да әйтеп уза : “ ... Дискотека – “товар” ны тарату-сату өчен иң кулай урын. Атнага бер оештырылган дискотекаларда Газинур һәм аның хезмәтчеләре атна буе эшләгәннән дә артык “товар” озаталар.“*[1]* Ә бит дискотекаларга яшьләр йөри. А.Фәләх бу турыда безгә уйланырга куша.

Шунысын әйтергә кирәк: Газинур наркотиклар таратуны аңлы рәвештә башкара. Ул наркотикларның кешене нинди дәрәҗәгә җиткерүен баштан ук белә, чөнки күршесе Юраның авыр халәтен күрә. Юрага врач буларак ярдәм итү урынына ул дозага акча бирә дә, үз бурычын үтәгән кеше кебек тынычланып кала.”Наркотиклар – рәхәт исереклек халәте, ә даими кулланганда анда күнегү һәм нык бәйлелек тудырырга сәләтле матдәләр*”[3]*булуын Газинур яхшы белә. Шуңа күрә дә үзе наркотиклар кулланмый. Ул наркотик колына әверелгән кешеләр, аларның гаиләләре кайгы-хәсрәт бәрабәренә мул тормышта яши.

Тормышта Газинур кебек наркомафия вәкилләре гадәттә озак яшиләр, аларның бөтен төштә үз кешеләре була. Ләкин язучы үз әсәрендә генә булса да, бу кабахәт җанга рәхәт тормышта тыныч кына яшәргә бирми. Газинур хата эшли, ул Галине - Хәмитнең сыйныфташын үтерә. Аны милиция эзли башлый. Борис Михалыч аны Чечняга “спецслужба”га дигән булып ял итәргә җибәрә. Газинур монда да тынычланмый, ул солдатларны кыйнап, җәберләп, үтереп, шакшылыклар эшләп, типтереп яши. А.Фәләх Газинурны тынычлыкта калдырмый, аны Әмирдән үтерттерә. Ягъни, яшьләрне юлдан яздырып, рәхәт тормышта яшәүче Газинур үз җәзасын ала.

Өченче төрке вәкиле – бу Хәмитнең гаиләсе. Наркотиклар проблемасы бу үрнәк, тату гаиләгә һич көтмәгәндә килеп керә. Автор әсәрендә ата-ананың уй- кичерешләрен күрсәтмәгән. А.Фәләх Әмир белән Ләйләнең кичерешләренә игътибар иткән. Бу ике геройны аерым-аерым карап китик.

Ләйлә бик чибәр, әле генә мәктәпне тәмамлаучы кыз һәм Хәмитнең апасы. Ул гел яхшы билгеләргә генә укый. Күңел ачып йөрергә яратмый, бер тапкыр дус кызлары бик кыстагач кына дискотекага бара. Бәхетсезлеккә каршы, ул Газинур белән таныша. Газинурның әдәплелеге, игътибар күрсәтүе аркасында Ләйлә аңа гашыйк була. Кызның ышанычына кергәч, егет аны көчли. Ләйлә балага уза, егеткә хәбәр итә, Газинур сорарга килергә вәгъдә бирә. Без бар да яхшы булыр дип тынычланып та өлгермибез, язучы Газинурның Ләйләне хатынлыкка алу нияте белән бармавын, ә аны ныграк мыскыллау өчен генә эшләвен күрсәтә.

Наркотикларны Лэйлә кулланмый да, таратмый да.Ул Газинурга гашыйк булып ялгыша. Наркотиклар бизнесы белән шөгыльләнеп, Газинур таш багырьле кешегә әверелә. Ул наркотиклар белән бәйләнмәгән булса, бу ике яшь кешедән матур, тату гаилә барлыкка килгән булыр иде. Ләкин наркотиклар дөньясында кешелек сыйфатларына, мәхәббәткә, гаиләгә урын юк.

Шундый түбәнсетүләр аша узган Лэйлә түзә алмый, сына. Ул үзенә кул салмакчы була, ләкин исән кала. Бик каты психик яра аны акылга зәгыйфь итә. Әйе, автор бу геройны исән калдырды, ләкин аның киләчәге якты булыр дигән өмет аз. Монда да наркотиклар бер дә гаепсез кешенең тормышын җимерде.

Наркотикларга каршы көрәшергә үзендә көч тапкан бердәнбер образ- Әмир. Әмир менә ярты ел хәрби хезмәт үтә һәм, кайнар ноктага барыр алдыннан, туганнарын күреп кайтыр өчен, аны берничә көнгә өенә җибәрәләр. Ул кайтуга ярты ел эчендә дус, тату гаиләсенең наркотиклар аркасында җимерелүем күрә. Әмир югалып калмый, ул энесе Хәмиткә шунда ук үз ярдәмен тәкъдим итә. Наркомания проблемасын ул бик ачык күзаллый. “ Уйларга да куркыныч. Мәктәптне дә тәмамламаган маңка малай упкын читендә басып тора ... *“[1]* – ди ул.

Әмир наркотиклардан үз энекәшен генә түгел, ә башка кешеләрне дә араларга тели. Моны без Хәмитне үз кулланмаган дозаны сатарга тәкъдим иткәндә, Әмирнең әйткән сүзләрендә күрәбез. “Син үзең турында гына уйлыйсың, энекәш. Башкалар агуланса да ярар дисеңмени*?“[1].*

Әмир наркомания проблемасының бөтен кешелек тарафыннан чишелә башлагач кына нәтиҗә китерәчәген белсә дә, көрәшергә була. Энесе үтерелгәч, ул наркотиклар таратучылар янына бара, аны кыйнап качалар. Үзенең бернәрсәдә эшли алмавына, эчке эшләр идарәсенең ярдәм итмәвенә Әмирнең йөрәге өзгәләнә.

“ ... Пычрак дөнья! Вәхшиләр, таш бәгырьләр дөньясы, “ – дип Әмир кайнар ноктага бара һәм, менә тормыш хикмәте, Газинурны очрата. Тормышта Әмир законлы юл белән Газинурга җәза бирә алмагач, А.Фәләх аңа үз гаиләсе өчен генә булса да үч алырга мөмкинлек бирә. Ул дөньяда булган бер генә булса да вәхиш җанны – Газинурны юк итә. Әйе, Әмир үзе дә үлә, ләкин канәгатьлелек хисен тоя ул шул мизгелдә “ ... кичерегез, башкача булдыра алмадым. Мин моны эшләргә тиеш идем ... Хуш ... сеңелем! Синең өчен үч ала алуымнан аз гына булса да канәгатьлек хисе тоеп китәм ... *“ [1]*

Әмир үлүе белән бергә бер гаиләнең буыннар чылбыры өзелде дисәк тә була. Тулы, матур гаилә ике малаен наркомания афәте аркасында югалтып, төптән корырга мәҗбүр була. Әлбәттә, әле Лэйлә исән, ләкин ул үз акылында түгел һәм сау-сәламәт бала таба алуы шик тудыра.

Наркомания дөньясы бер гаиләне вәхшиләрчә таптап, инде рәтләнмәс итеп изеп китә. Ә хәзерге вакытта мондый гаиләләр бик күп. Наркомания кешелек дөньясын җир йөзеннән бөтенләй югалуга якынайта.

Амур Фәләхнең гомумкешелек проблемасын күтәргән әсәр язуы игътибарга лаек. Шуны әйтергә кирәк: язучының бу мәсьәлә буенча әсәр язу өчен, бик күп мәгълүмат җыюы; проблемага бик җитди каравы, аңа тирән кереп өйрәнүе күренеп тора. Әсәр реаль фактларга нигезләнеп язылган. Як-ягыбызга карасак, мондый күренешләр, гаиләләр тулып ята. А.Фәләх бу тормыш күренешләрен күреп, каләменә салып, безгә җиткерергә омтыла.

“Таш бәгырь” әсәрендәге геройлар наркотиклар дөньясына төрле юл белән киләләр, ләкин бу юлның ахыры гел аянычлы. Наркоманнар үз тормышларын гына җимереп калмыйлар, ә тирә-яктагы кешеләрнең дә тормышларын агулыйлар.

Язучы әсәрендә Әмир теле белән бик мөһим фикер әйтә: “Упкын! Бар кешелек упкынга тәгәри. Менә газета-журналлар, телевидение аша үгетлә син ул яшьләрне! Файдасы бармы соң?! Наркомафия бөтен кешелек дөньясын үз кулында тота шул. Алар шушы бизнес белән яши. Куркыту, көчләү белән! ...*”[1]*

Без “Таш бәгырь” әсәрендә сурәтләнелгән наркомания дөньясының өч төрле вәкилен карап уздык. Шунысы әһәмиятле: бу вәкилләрнең берсе дә бәхеткә ирешмәде. А.Фәләхнең

әсәрен шулай төзүе очраклы түгел, ул наркотикларның бөтен нәрсәне юкка чыгаручы афәт икәнлеген дәлилли.

Наркотиклар дөньясында иң кыйммәтле әйбер- ул акча, кеше гомере монда бернәрсәгә дә тормый. Кешелек мөнәсәбәтләре, гаилә, мәхәббәт бу дөнья өчен чит, ят сүзләр. Наркоманиянең үтерү машинасы мәрхәмәт, кызгану хисен белми. Ул юлына очраган һәр әйберне изеп китә.

А.Фәләхнең “Таш бәгырь” әсәреннән күренгәнчә, наркотиклар булган дөньяда гади кешегә, саф хисләргә урын юк. Бу- акча һәм кеше бәхетсезлеге бәрабәренә мул тормышта яшәүчеләр дөньясы. Шулай итеп, безнең тикшеренү эшенең гипотезасы расланды. Акча һәм мул тормыш өчен, кешеләр наркотиклар сата, бер-берсен наркомания дөньясына этәрә.

*Кулланылган әдәбият:*


1. Амур Фәләх. Таш бәгырь: Повесть, новелла, хикәяләр. - Казан: Тат.кит.нәшр., 2004 – 127 б.
2. Вахит Имамов. Таныш булыгыз : Амур Фәләх //Мәйдан. Казан, 2002. - №3 – Б 8-30.
3. Наркомания : моны һәркем белергә тиеш / Төзүчеләр : Р.Г.Садыкова, Л.А.Кудряшова. – Казан : “ДАС”, 2001 – 21 б.
4. Сальмушев Р.Х. Ләйләгә рәхмәт. – Казан : РНЦ “Школа”, 2004 – 34 б.
5. Хәсәнова Г.Г. Наркоманнар безнең арада // Хезмәт даны. Кукмара, 2011.-№32 – Б2


## НӨНӘГӘР ҖИРЛЕГЕ АНТРОПОНИМИКАСЫ


*Хәйруллина Гөлия, 6нчы сыйныф укучысы*

*Фәнни җитәкче: Балтач районы МБГБУ “Нөнәгәр гомуми урта белем мәктәбе”нең*
*югары категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы*
*Гыйльфанова Рәзинә Нургаян кызы*


Антропоним термины кешеләрне атау өчен хезмәт итә торган исем, отчество, фамилия, кушамат һәм псевдоним төшенчәләрен аңлата. Ономастиканың бу тармагы элек - электән кешелектә зур кызыксыну тудырган. Замана үзгәргән саен, исемнәр кушуда да үзенчәлекләр сизелә. Тел гыйлемендә антропонимика фәне белән кызыксыну 20нче гасыр урталарында башланган булса да, ул әле дә тулысынча өйрәнелеп бетмәгән тармак булып санала.

Җир шарында һәр милләт халкы яңа туганнарга үзләренә генә хас булган, нindидер мәгънәгә ия исемнәр кушкан. "Исемең кем? Исемеңнең мәгънәсе нинди? Нәрсә аңлата? Исемең җисемеңә туры киләме?” кебек сорауларны соңгы вакытта еш ишетергә туры килә.

Менә шуларны исәпкә алып, мин “Нөнәгәр җирлеге антропонимикасы” дигән фәнни эшкә алынырга булдым.

***Теманың актуальлеге***: балаларга төрле исемнәр кушыла. Араларында колакка ятышсыз, мәгънәләре буенча ямьсезләре дә очрый. Әти-әниләр балаларына мәгънәле исемнәр кушсыннар иде.

***Максат:*** антропонимика төшенчәсен өйрәнү, авыл җирлеге буенча исем кушылышын һәм кушаматлар тагылышын тикшерү, күп таралган исемнәрне барлау, мәгънәләрен ачыклау, кушаматларны квалификацияләү.

***Фәнни эшебезнең бурычлары:***

- Г.Ф. Саттаровның антропонимикага кагылышлы хезмәтләрен өйрәнү;
- Нөнәгәр җирлеге буенча кушаматларны барлау, мәгънәләрен ачыклау максатыннан, миниэкспедицияләр оештыру;
- Нөнәгәр җирлеге буенча 1960- 2018нче елларда нинди исемнәр күп кушылган, авыл җирлеге кенәгәләре буенча шуларны барлау;
- Нөнәгәр мәктәбе буенча иң күп кушылган исемнәрнең мәгънәләрен ачыклау;
- Кушаматларны классификацияләү;

***Өйрәнү объекты:*** Нөнәгәр авыл җирлеге кенәгәләре; Нөнәгәр мәктәбендә укучы балаларның исемнәре, кушаматлары. ***Хезмәтнең гамәли әһәмияте:*** исем кушкан вакытта эти-әниләр бу хезмәттән файдалана ала. Фәнни хезмәт барышында эзләнү, өйрәнү, чагыштырма анализ методлары кулланылды. Кушаматларны классификацияләү Гомәр Фәизович Саттаров методикасына нигезләнеп башкарылды.

Туган ягыбызның махсус төбәк буенча өйрәнелмәве иҗади эзләнүләргә юл ачты. Теманы ачу өчен материал туплау шактый кызыклы булды. Темага кагылышлы әдәбият белән якыннан танышырга, авылымның аксакаллары белән очрашып сөйләшергә туры килде. Кушаматлар туплау, исемнәрнең мәгънәләрен ачыклау бигрәк тә кызыклы һәм мавыктыргыч булды.

Антропоним термины кешеләрне атау өчен хезмәт итә торган исем, отчество, фамилия, кушамат һәм псевдоним төшенчәләрен аңлата. Һәр телнең билгеле бер рәсми һәм рәсми булмаган номинатив категорияләрдән гыйбарәт антропонимик системасы бар. Рәсми антропонимик категория булып, исем, фамилия, отчество саналса, рәсми булмаган категориягә кушаматлар керә. Исем, отчество, фамилия белән эндәшү безнең төбәктә, күрше Киров өлкәсенә караганда (анда руслар яши), соңрак кергән.

Исем - кеше холкының коды, аның җиргә нинди максат белән килүен белдерүче билге. Ата – ана исемне уйлап сайларга тиеш, чөнки балаларының язмышын алар билгели. Яңа туган сабыйга исем эзләгәндә, җиңел әйтелешле, аһәңле, мәгънәле, ул исемнең җыйнак булуына караганнар. Татар халкының киләчәк буынының язмышы, аларның милли гореф-годәтләре, мәгърифәте, мәдәнияте, сабыйларның исеме белән турыдан туры бәйле. Галим Гомәр Фәизович Саттаров сүзләре белән әйткәндә: “Татарча милли исемнәр татарлыкны, татар халкының милли йөзен, төсен, сыйфатын, тарихи үткәнен, бүгенгесен һәм киләчәген тиешенчә саклый һәм яклый “.[ Саттаров Г. “Исемең матур, кемнәр куйган?”] Татарларда исемнәр фамилия ясауда да зур роль уйнаган. Чыннан да, бездә башка милләт вәкилләреннән аермалы буларак, мәгънәсез фамилияләр бик сирәк очрый.

Һәрбер төбәктә кеше исемнәренең шактый кызыклы һәм бай тарихы, гаять үзенчәлекле һәм тотрыклы традицияләре бар. Кушаматларда да без халыкның тел байлыгын, тормыш – көнкүрешен, гореф-гадәтләрен, рухи халәтен ачык тоябыз..

Авылыбызда татар кеше исемнәренең күбесе җыйнак төзелешле, җиңел әйтелешле. Мондый борынгы исемнәребез 3 төрле юл белән ясалганнар.

Бер ишеләре 3 яки 2 иҗекле тамыр сүздән гыйбарәт күмәк сүзләрнең кеше исеменә әверелүе нәтиҗәсендә барлыкка килгән: Булат, Алмаз, Чулпан, Энҗе, Ландыш, Ләлә һ.б.

Икенчеләре бер яки ике иҗекле тамыр сүзләр кушылып ясалган: Айнур, Илназ, Гөлзифа, Гөлнур, Илшат, Илсөяр, Илһамия, Илдус, һ.б.

Фонетик юл белән ясалган исемнәр: Илназ – Илнар- Илдар - Илфар; Рәзинә - Рәзилә - Рәмилә; Ринат – Рифат – Ришат; Фәрит – Рәфит; Фәнил – Фәнис – Рәнис – Рәмис һ.б.

Элеккеге исемнәр арасында алынма исемнәрне кыскартып әйтү, нигездә иркәләү – кечерәйтү кушымчалары ярдәмендә формалашкан :

- Хәйбулла –Хәйбуш; Габдулла – Апу; Калетдин – Камай; Мифтахетдин – Митак; Фәсхетдин – Фәсхи; Әсхәдулла - Әскәй һ.б.

Исемнең соңгы иҗеген кыскарту:

- Җәүһәрия – Җәүһәр; Гәүһәрия – Гәүһәр; Җиһания – Җиһан; Шәмсениса – Шамса, Шәмсеҗиһан – Җиһан һ.б.

Кушма тамырлы исемнәрнең беренче өлешен ташлап, икенче өлешен генә әйтү: Миңсылу – Сылу; Гөлзифа – Зифа; Маһисәрвәр – Сәрвәр; Гөлбикә- Бикә.

Җәмгыятьтә барган һәртөрле яңалык телнең үсешенә дә йогынты ясый. Шул исәптән, кеше исемнәре дә һәрчак үзгәреп тора. Безнең Нөнәгәр җирлеге буенча исемнәр ни рәвешле үзгәреш кичергән икән? Шушы максаттан чыгып, без җирле үзидарә кенәгәләреннән 1960-2018нче елларны күзәттек. ( Кушымта №1)

**1960 – 2018нче еллар аралыгында Нөнәгәр авыл җирлеге буенча иң күп кушылган исемнәр.**

| № | Вакыт | Күп кушылган исемнәр | Заманага ияреп, кушылган исемнәр |
|---|---|---|---|
| 1 | 1960-1965 | Рәис, Рәйсә, Ринат, Наил, Рифат, Рузилә. Нурсия, Раузит, Раушан, Раушания, Марат, Равил, Равилә, Гөлфия, Зөлфия, Дамир | Марат, Люция |
| 2 | 1966-1970 | Әлфия, Раушания, Равил, Ринат, Илфат, Фирдинанд, Марсель, Илфак, Раил, Ранил, Фәридә | Марсель , Люция, Марат |
| 3 | 1971-1975 | Рамил, Фәрит, Рәмзия, Альмира, Люция, Рамил, Фәрит, Рәмзия, Илнар, Гөлнур(а), Нурзия, Илдар, Лилия, Илүсә | Эльза, Люция, Альмира, Альбина, Эльза, Роберт, Марсель, Венера, Индира, Радик |
| 4 | 1976-1980 | Илдар, Илнар, Илүсә, Нияз, Рәмзия, Ләйсән, Гөлнара, Гөлназ, Рамил | Роберт, Ильвира, Ленар |
| 5 | 1981-1985 | Рафил, Фәнзия, Илшат, Гөлфия, Раил, Зөлфия | Эльвира, Руслан |
| 6 | 1985-1990 | Айгөл, Ләйсән, Гөлназ, Рөстәм, Фәнис, Ләйлә, Ранил | Ленар, Эльвира, Рафаэль, Динар, Фидарис, Марат, Марсель |
| 7 | 1990-1995 | Әнисә, Алсу, Гөлфинә, Рүзәл, Рөстәм, Айгөл, Алия, Рәмзил, Ләйсән, Алинә | Марсель, Ильяс, Ильмир, Альмир, Альбина |
| 8 | 1995-2000 | Илназ, Лилия, Салават, Рүзәл, Рәмзил | |
| 9 | 2000-2005 | Алинә, Гөлинә, Ислам, Мәликә | |
| 10 | 2005-2010 | Ислам, Әмир, Алмаз, Динә | |
| 11 | 2010-2018 | Әмир, Зилә, Алмаз, Диләрә, Әдилә, Азалия | Асель |

Таблицадан күренгәнчә, заманага яраклашу 1960-1995нче елларга чаклы күзәтелә. Колакка ятышсыз, мәгънәләре “сәер” исемнәр нәкъ менә шушы чорда кушылган.

Алдагы еллар белән чагыштырганда, элекке исемнәргә әйләнеп кайту тенденциясе күзәтелә. Авылыбызның балалар бакчасына Сәйдәш, Ислам, Әмир, Юнысларның йөрүе моның ачык дәлиле булып тора.

Соңгы елларда заманча да, дингә дә бәйләнешле исемнәр кушыла башлады. Ир – балалар арасында кушылган исемнәр: Рәзил, Фәнзил, Рәмзил, Илназ, Ислам, Рәсүл, Рүзәл, Рәниф, Әмир һ.б. Кызлар арасында Айгөл, Гүзәл, Гөлназ, Зилә, Ләйсән, Алсилә, Дилә, һ.б. исемнәр популяр.

**МБГБУ "Нөнәгәр ГУБ мәктәбе" буенча кушылган исемнәр.** Безнең мәктәптә 124 укучы укый. Мин шушы исемнәрне тикшерердем. Нәтиҗәдә иң күп кушылган кыз һәм малай исемен билгеләдек. Барлыгы 68 малай һәм 56 кыз исемнәрен тикшергәннән соң, түбәндәге нәтиҗәләргә килдем:

**Малайлар арасында күп кушылган исемнәр**

| Исем | Саны | Барлык баланың % | Классы |
|---|---|---|---|
| Алмаз | 7 | 10% | 2,3,5-2,6,8-2 |
| Ислам | 4 | 5% | 1,4,8,9. |
| Рәзил<br>Айнур<br>Салават | 3<br>3<br>3 | 4,2% | 2,6,4.<br>3,7,10.<br>5,5,10. |
| Зөлфәт<br>Әлфис<br>Илназ<br>Илмир | 2<br>2<br>2<br>2 | 2,9% | 5,6.<br>8-2<br>2,5.<br>8,10. |

- Ир бала исемнәре буенча беренче урында Алмаз исеме тора. "Татар исемнәре" сүзлегеннән караганда, Алмаз – асылташ дигән сүз.
- Икенче урынга чыккан Ислам исеменең сүзлектә 3 мәгънәсе бирелгән: Аллаһыга буйсыну, күндәмлек; мөслим, мөселман; сәламәт, сау.
- Өченче урынны Рәзил, Салават һәм Айнур исемнәре бүлеште. Рәзил тамга, билге дигән мәгънәне аңлатса, Айнур исеме – ай нуры дигәнне аңлата. Ә Салават исеменең сүзлектә 2 мәгънәсе бирелгән: догалар, мактау җыры; фатиха бирү;

4нче урынга 4 исем чыкты. Илназ исеменең мәгънәсе ил һәм наз сүзләреннән ясалган. Илмир – яхшы күркәм, шөһрәтле, Әлфис, Зөлфәт, Рәсим исемнәренең сүзлектә мәгънәләре бирелмәгән.

**Кызлар арасында күп кушылган исемнәр**

| Исем | Саны | Барлык баланың % | Класссы |
|---|---|---|---|
| Чулпан | 3 | 5,3% | 6кл -2, 11кл -1 |
| Айгөл | 3 | 5.3% | 1кл-1, 7кл-1, 8кл -1 |
| Гөлшат<br>Гөлия<br>Зилә<br>Энҗе<br>Финзия | 2 | 3,5% | 5кл – 1, 9кл – 1<br>5кл – 1, 3кл - 1<br>2кл – 1, 9кл - 1<br>5кл – 1, 9кл - 1<br>5кл – 1, 9кл - 1 |

- Беренче урындагы кызларыбызның исемнәре түбәндәге мәгънәләрне белдерәләр: Чулпан – таң йолдызы; Айгөл - алсу йөзле, матур, чибәр.

- Икенче урынга 5 исем чыкты. Зилә исеменең сүзлектә 2 мәгънәсе бирелгән: миһербанлы; таза –саф, керсез; Гөлия – гөл кебек; Гөлшат – шатлык гөле; Ландыш - энҗе чәчәк; Энҗе – Көнчыгыш халыкларында энҗе бәхет юлдашы булып саналган.

Галимнәр исәпләвенчә, татар телендә хатын – кыз һәм ир-ат исемнәренең күләме 25 меңнән артып китә. Күләме һәм төрлелеге ягыннан татар исемнәренә дөньяда тиңнәр юк. Бу төрлелекне мин үземнең кечкенә генә тикшерү эшемдә күрдем.

**Кушаматларның мәгънәләре ягыннан төрләре**

Кеше исемнәре белән беррәттән, шәхесне атау өчен, кушаматлар киң кулланылган. Авылымда кушаматсыз кеше юк диярлек. Кушамат - ике сүз кушылу юлы белән ясалган, “кушам” “ат” дигәннән алынган. Билгеле булганча, иске татар телендә ат сүзе исем мәгънәсендә йөргән. Антропонимика өлкәсенә үзеннән бик зур өлеш керткән Гомәр ага Саттаров үзенең “Татар антропонимикасы” дигән хезмәтендә болай дип язган: “Кушаматның тискәре функциясе булмаган. Ул, күбесенчә, нәсел тамгасы, нәсел ыру атамасы (патроним) яки шәхеснең рәсми булмаган беренче (төп) исеменә өстәмә икенче исеме (кушма, тагылма аты), рәсми булмаган “урам исеме” булып йөргән” [“Татар антропонимикасы”, 225 нче бит.] Кушаматлар аралашуны, аңлашуны җиңеләйтү, кем турында сүз алып баруны төгәл, ачык итеп әйтү өчен ярдәм итә торган бер антропонимик чара булып торалар. Кушаматлар тарихы бик кызыклы. Алар шәҗәрә кебек озын гомерле. Буыннар дәвам итә, кемгәдер тагылган кушамат, нәсел җебе кебек, безнең көннәргә кадәр килеп җиткән.

Әлбәттә, кушаматлар булган хәлләргә, кешенең гамәленә, гадәтенә, характерына бәйле. Алар лексикабызның аерылгысыз тармагын тәшкил итәләр. Бездә кәҗә Нурзада дигән кеше бар. Алар элек-электән күп итеп кәҗә асраганнар, кушаматлары шуннан калган. Ә менә карга Гарифулласы дигән кешегә кушамат тагылуы бик тә кызыклы. Үрдәк чалганда, эшнең ахырына кадәр төгәл эшләнмәве аңа кушамат тагылырга сәбәп булган. Башсыз үрдәк торып китә, ә моны хатыны: “Шулай була ул, эшеңне җиренә җиткермәсәң, калдыңмы карга кебек авызыңны ачып,” – дигән. Сафа яшьлегендә шактый гайрәтле кеше булган. Бу гадәте картайгач та, үзеннән калмаган. Холыксыз вакытында эт булып та өргән, бүре булып та улаган. Шуннан аңа “бүре” кушаматы ябышып калган. Аның бу кушаматы инде дүртенче буын вәкилләренә тагылган. Автомат кушаматы Фәйзелхак дигән кешегә бик кызу аңлаешсыз, автоматтан аткан кебек сөйләшкәнгә кушылган. Балалары, оныклары шулкадәр кызу булмасалар да, “автомат“ кушаматын йөртәләр. Китек Наил кечкенә вакытында ат тибеп, борынсыз калган. Борын урынында борын тишекләре генә ямьсез булып торалар. Кушаматы шуннан килеп чыккан. Ә менә тумыштан колагы булмыйча туган Наил абыйның кушаматы -“Ушаков”. Кәләйнекеләрне кушаматы калай сүзеннән бозып әйтелгән. Аларның ерак бабалары төбәгебездә калайдан әйберләр ясый белә торган беренче кеше булган. Аңа төрле җирләрдән калайдан әйберләр эшләтергә килгәнннәр. Нәтиҗәдә бу кушаматны хәзер дүртенче буын вәкилләре йөртә. Песи Шамиленә песи кебек йомшак, сак булганы өчен ябышкан кушаматны авылда алар нәселеннән булган берничә гаилә йөртә. Җомга кушаматы Нургаянга бер дә юктан гына тагылган. Абыйсы янына килгән берәү куркыткач, ул ике кулын күтәреп катып кала. Ә бу кеше күптән түгел генә Робинзон Крузоның китабын укыган була. “ Кара әле, - ди бу кулын күтәргән малайны күргәч, - бу Крузоның Җомгасы кебек икән”. Шул көннән ябышкан кушаматны бүген Нургаян бабайның оныклары да йөртәләр. Золотой Рафаэль бик мактанчык кеше булган. Һәр нәрсәне, алтынга манып, күпертеп сөйләгәч, аны “Золотой” дип йөртә башлаганнар. Чирла Гилманга кушаматы тимерчелектә эшләгәндә тагыла. Кәләбетинекеләргә дә кушамат юктан гына тагылып кала: көтү кайткан вакытта кечкенә Наил сакау теле белән: “ Әнә безнең кала бәти кайта”, - дип кычкырып җибәрә. Ә якын тирәдәгеләргә ул кәләбети булып ишетелә. Шулай итеп, Наил абыйның оныклары да хәзер “кәләбети” булып йөриләр. Мариныкылар нәселенә кушамат Мари ягыннан күченеп кайтканга бирелгән.

**Кушаматларны функцияләре буенча төркемләү**

Башкара торган функцияләренә карап, татар телендәге кушаматларны берничә төркемгә бүлеп йөртәләр: шәхси кушаматлар; нәсел кушаматлары; коллектив территориаль кушаматлар.

Безнең авылда шәхси һәм нәсел кушаматлары киң таралган. Шәхси кушаматлар шәхес характерының үзенчәлегенә, профессиясенә һәм башка шәхес үзенчәлекләренә мөнәсәбәтле рәвештә туган. Алар реаль чынбарлык белән тыгыз бәйләнешле. Шәхси кушаматлар кешенең характеры, төс – бите, физик кимчелеге, милли чыгышы, профессиясе Һ.б. нигезләнеп кушыла. Мәсәлән: мичче Гарифулла (Гарифулла абый авылда пич чыгару остасы булганга кушылган), духтыр Мәлик ( Нуриев Мәлик абый гомере буе хайваннар врачы булып хезмәт иткән. Шул ук вакытта малайларны сөннәткә утырту, гозер белән килгән кешеләрнең тешләрен алу кебек вазифалар да башкарган), бүре Рәис (кешегә бүре кебек караган), полтора Равит (авылдагы иң озын кеше. Шунысы кызык: аларның нәселендәге барлык кешеләр дә шундый эре сөякле, озын булсалар да, мондый кушамат Равит абыйга гына кушылган), песи Шамил һ.б.

Нәсел кушаматларының килеп чыгышын, мәгънәләрен татар халкының борынгы бабалары яшәгән чордан, болгар катламыннан һәм башка кардәш, кардәш булмаган телләр материалларыннан эзләгәндә генә ачыклап була. Кайберләре: Тархан Фәсхетдин, Тумак Нәкыйбе, Аксак Галимулла һ.б.

Коллектив – территориаль кушаматлар бер төркем кешеләргә яки аерым авыл, төбәк, поселок кешеләренә тагылган. Безнең авыл ир – атлары, авылда хезмәт хакы тиешенчә түләнмәгәнгә күрә, төрле төбәкләргә балта эшенә йөри. Халык телендә “шабашник” дип йөртеләләр. Башка авыллар өчен Нөнәгәр авылы “шабашниклар авылы” булып йөри. Ә кешеләре – “шабашник авылы кешеләре”. Шулай ук авылыбызның бер урамы “Котылдык” урамы дип атала, ул иң яңа урамнардан санала. Төп йорттан аерылып, башка чыгучылар шул урамга урнашканнар һәм кайнана, кайната яныннан чыгып китүләренә сөенеп, “Котылдык”, - дип әйткәннәр имеш. Шушы урам кешеләре “котылдык” кушаматын йөртәләр.

Шулай ук авылдагы кушаматларны барлаганнан соң, аларны микропотонимнарга, шәхеснең һөнәр - кәсебенә, тышкы кыяфәтенә, физик кимчелекләргә, хайван атамаларына һ.б. нигезләнгәннәрен дә төркемләдем:

1. Антропонимнарга нигезләнеп ясалган кушаматлар: Камай Габделхак, Кәртәш Нурисламы (Кәлимуллин), Аптуш малае (Габдулла), Теләк Мансуры, Бураш Котдусы, Изәт Сәгыйте( Гыйззәт солдат нәселеннән).
2. Шәхеснең һөнәр – кәсебе белән бәйле кушаматлар: мичче Гарифҗан, духтыр Мәлик, Кәләй Нургаянһ.б.
3. Шәхеснең тышкы физик билгеләрен характерлаучы кушаматлар: китек Наил, холодец Наил, аксак Нургаян, полтора Равид.
4. Кош- корт, хайван исемнәре белән бәйле кушаматлар: кәҗә Нурзада, бүре Рәис, тити Фарук, чеби Габделхай, песи Шамил, ишәк Харис, чәүкә Фәнил, тукран Рафис.
5. Бөҗәк, үсемлек атамалары: таракан Гайфи, әрлән Рашит, карбыз Нургаян
6. Кешенең характерын билгели торган кушаматлар: кислота Рәйсә, Мәскәү Миңлегөл, Опасный Рәис, автомат Фәйзелхак.
7. Көнкүреш кирәк – яраклары: Пычкы Ранил.
8. Милләтенә карап бирелгән кушаматлар: мари Фәйзелхак.
9. Шаярып әйтелгәннән калган кушаматлар: җомга Нурган.
10. Бала – чага сөйләменнән сакланып калган кушаматлар: кәләбети Наил (кара бәти дигән бозып әйтелгән)
11. Балалар арасында, күренекле шәхескә охшарга тырышып кушылган кушаматлар: Рональдо, Илмир, Рембо Рөстәм һ.б.

Кушаматларның берничәсенә генә тукталып кителде. Шунысы гаҗәп: авылда кушаматсыз кеше юк диярлек. Кушамат тагучыга да, кушамат белән эндәшүчегә дә үпкәләмиләр бездә.

Теманы ачу барышында түбәндәге эшләр эшләнде:

- Г.Ф. Саттаровның антропонимикага кагылышлы хезмәтләре өйрәнелде;
- Нөнәгәр җирлеге буенча кушаматларны барлау, мәгънәләрен ачыклау максатыннан миниэкспедицияләр оештырылды;
- Нөнәгәр җирлеге буенча 1960- 2011нче елларда нинди исемнәр күп кушылганлыгы авыл җирлеге кенәгәләре буенча барланды, нәтиҗәләр чыгарылды;
- Нөнәгәр мәктәбе укучылары арасында анкеталар алынды;
- Нөнәгәр мәктәбе буенча иң күп кушылган исемнәрнең мәгънәләре ачыкланды, нәтиҗәләр чыгарылды;
- Кушаматлар классификацияләнде.

Эзләнүнең нәтиҗәләре:

- Авылымда борынгы болгар – татар кеше исемнәренең күбесе җыйнак төзелешле, җиңел әйтелешле. Мондый борынгы исемнәребез 3 төрле юл белән ясалганнар.
- Заманага яраклашу 1960-1995нче елларга чаклы күзәтелә. Колакка ятышсыз, мәгънәләре “сәер” исемнәр нәкъ менә шушы чорда кушылган.
- Элекке исемнәргә әйләнеп кайту тенденциясе күзәтелә. Соңгы елларда заманча да, дингә дә бәйләнешле исемнәр кушыла.
- Ир – балалар арасында кушылган исемнәр: Рәзил, Фәнзил, Рәмзил, Илназ, Айнур, Ислам, Рәсүл, Рүзәл, Рәниф, Әмир һ.б.
- Кыз балалар арасында Айгөл, Гүзәл, Гөлназ, Зилә, Ләйсән, Алсилә, Дилә, һ.б. исемнәр популяр.
- Нөнәгәр мәктәбе буенча кушылган исемнәр арасында иң популяр исемнәр: Алмаз, Илназ, Рүзәл, Айнур, Булат, Ислам, Фәнзил, Алинә, Чулпан, Гөлфинә, Зилә, Алсу һ.б.
- Авылда кушаматсыз кеше юк диярлек. Авылның 27, 5% кешесе үз кушаматы белән горурлана, 50% кешесе битараф, 14% кешесе кушаматыннан канәгать түгел, бигрәк тә яшьләр арасында күзәтелде.
- Шәхси кушаматлар нәсел кушаматларына караганда күбрәк .

*Файдаланылган әдәбият:*
1. Я.Х. Абдрахимова “Исемең матур, кемнәр куйган?” Казан, 2002 ел
2. Гомәр Саттаров “ Исемең матур, кемнәр куйган”. Казан, 1989 ел.
3. . Гомәр Саттаров “ “Татар антронинимикасы”. Казан, 2000 ел.
4. Гомәр Саттар-Мулилле “Татар исемнәре ни сөйли?” Казан, 1998 ел.
5.”Ислам дине йолалары вә гореф-гадәтләре.”Казан, 2001 ел.
6. Ф.С. Сафиуллина “Тел дигән дәрья бар...” Казан, 1979 ел.

*Файдаланылган чыганаклар:*
1. Авылым аксакаллары истәлекләре.
2. “Кәшифә Тумашева исемендәге” музейда сакланган истәлекләр.

## ТАТАР БАЛАЛАР ӘДӘБИЯТЫНДА АТ ОБРАЗЫ

*Хуҗиатуллин Денис Альберт улы,*
*Саба районы Шәмәрдән лицее, 9 нчы сыйныф укучысы*
*Фәнни җитәкче: Галимҗанова Диләрә Илгиз кызы*

Ат — элек-электән татар халкының гомерлек юлдашы, иптәше, туйдыручысы булган. Әлеге йорт хайваны сугыш елларында да, тыныч вакытта да һәрчак кешегә тугры хезмәт иткән. Ат— иң күңелле бәйрәмебез Сабантуйда гаярь малайларны атландырып бәйгедә

катнашучы да. Элеккерәк заманда малайлар төннәрен ат сакларга баруны бик зур мәртәбә санаганнар. Атка атланып йөрү, ат коендыру... Авыл малае өчен әйтеп бетергесез куаныч бу! Шуңа күрә дә халкыбыз бик борынгыдан халык авыз иҗаты әсәрләрендә ат турында мәкаль, табышмак, тизәйткеч, җырларга зур урын биргән.Язучыларыбыз да ат турында матур-матур шигырьләр,җырлар,әсәрләр иҗат иткәннәр.Ат образы аларны иҗат эшенә дәртләндергән.Ник дигән дә язучыларыбыз күбесе авыл җирлегендә үскәннәр.Авылны атсыз күзалдына китерү мөмкин дә түгел, атның бетүе авылларның юкка чыгуы ул.Алар менә шул мәсьәләләрне үз әсәрләре аша безгә җиткерергә теләгәнннәр.Шулай ук Корьән аятьләрендә дә ат турында бик кызыклы итеп язылган. Әби-бабаларыбыз юкка гына атны олыламаганнар.

Беренчедән, ул-иң зур сугыш коралы ("Әнфәл" сүрәсе, 60нчы аять). Шуңа күрә дә Коръәннең 100 нче сүрәсе "Чабучы сугыш атлары" дип атала. Гарәп илләрендә һәм Төркиядә бүгенге көндә дә ат ите ашамыйлар, чөнки аларның гореф-гадәтендә ул кыйммәтле сугыш коралы, матурлык, дәрәҗәлек.

Икенчедән, ат-ул бәрәкәт малы, йортка иминлек бирә: "Ялларыннан бәйләнеп куелган йорттагы ат-кыямәт көненә кадәр хәерле",-диде Рәсүлебез (Бохари, 28520нче хәдис). Бу фәкать атка гына кагыла. Хәтта иң яхшы дөя дә кыямәт көне алдыннан эшсез, хаҗәтсез булыр, ә хайваннар зоопарк кебек урыннарда гына калыр ("Тәквир"сүрәсе, 4-5нче аятьләр).

Өченчедән, ат кешене төрле куркынычтан саклый.

Аллаһы Тәгалә: "Аттан Аллаһының дошманнары, сезнең дошманнар һәм сез белмәгән башкалар курка",-диде ("Әнфәл" сүрәсе, 60нчы аять). Ягъни безне дошманнардан, Аллаһ дошманнарыннан һәм без белмәгән җеннәрдән, төрле чирләрдән, сихердән, күз тиюләрдән саклый.

Дүртенчедән, "йортында карт ат булса, бу өйнең кешеләрендә акыл зәгыйфьлеге һәм чирләре булмас", -диде Рәсүлебез (Табарани) яки "Ат булган йортка җеннәр якын килмәс, чөнки алар кешнәвеннән качалар". Бу хәдисләр бик көчле булмасада, бүгенге табиблар моны бик уңай файдалана һәм атның яхшы тәэсирен үзләренең тәҗрибәләре белән исбат итә. Ләкин дәваланганда кыңгырау тагылырга тиеш түгел, чөнки: "Кыңгыраулы атка рәхмәт фәрештәләре иярми",-диде Рәсүлебез (Албани, 2112нче хәдис). Бу дөрес хәдистән аңлашыла: атка фәрештәләр иярә, ә шайтаннар кача.

Бишенчедән, атта йөрү җитезлек, кыюлык тәрбияли.

Бу хезмәтнең максаты балалар әдәбиятында Ат образын тикшерү.

Төп максатка ирешү өчен безнең тарафтан түбәндәге мәсьәләләр хәл ителде: шагыйрьләрнең ,язучыларның иҗаты өйрәнелде; ат темасына кагылышлы хезмәтләр өйрәнелде; шагыйрь һәм язучыларның кырык дүрт хикәясе һәм шигыре тикшерелде.

Теманың актуальлеге: Язучыларыбыз иҗатында Ат образын тикшерү авылларның хәзерге халәтен күзалларга ярдәм итә. Әлеге теманы өйрәнү балаларның атка булган мәхәббәтләрен ачыкларга булыша.

Ат дип әйтүгә сөекле шагыйребез Г.Тукайның “Пар ат” шигыре искә төшә.

Җиктереп пар ат,Казанга туп-туры киттем карап;
Чаптыра атларны кучер,суккалап та тарткалап [36:36].

Әйе, ат беренче чиратта транспорт чарасын башкарган. Хәтта язучы Гәрәй Рәхим ат турында тел күнектергеч тә язган. Ул «Атлас һәм Атлант» дип атала.

Аты атлап барганда да
Атлас аңа атлана.
Аның ап-ак яллы аты
Атлант диеп атала.
Атлас җилдәй җилеп бара,
Атлант уктай атыла.
Алты малай авыз ачып
Кызыгып карап тора[30:23].

Р.Бәшәрнең «Болындагы ат» шигыре. Бу шигырьдә шагыйрь үзенең балачагында күргән атын сурәтләгәндер. Шигырьне укыгач, минем дә колагыма ат кешнәгән тавыш

ишетелгән кебек булды. Ә менә М.Әгъләмовның «Бүләк» шигырендә яңа туган нәни колын турында язылган. Колын — ат баласы. Болын аңа күпме күчтәнәч бирә, кочагын ача. Хәзер инде колыннарны авылларда да сирәк күрәсең. Чөнки авылда да атлар бетеп бара.Шулай ук шагыйрь «Ат турында»дигән шигырендә чагыштырулар кулланып ат белән шагыйрь Ренат Харисны тиңли:

Картлар әйтте:
Яхшы кара,кал белеп,
Кешелек барында бу ат Мәңгелек![1:87]

Шагыйрьләр атлар турында юмористик шигырьләр дә язганнар.Нур Гайсинның "Минем атым" һәм Ш.Галиевнең «Колынкай» шигырьләрендә уенчык ат колыны турында бик матур итеп языла. Малай уенчык атын бик ярата. Җәй көне тере колынны күрүе белән горурлана. Ә менә "Ат "йөртүче" малай" Л.Леронның "На-а,бахбай",Р.Мингалим "Велосипед"шигырьләрендә малайлар мотоциклны, велосипедны, урындыкны ат итеп уйныйлар.Авыл малайлары шәһәр кунагына менә мондый киңәш бирәләр:

Әйттек кунак егеткә:
- Озак булыр аңлату,
Тормоз белү-бер нәрсә,
Кирәк атны ярату[10:78].

Фәннур Сафинның "Яшь тай", "Ярсу ат" шигырьләрендә ireккә омтылырга яратучы Ат образы тасвирлана.

Безнең кебек ул ат та
Туган җирне ярата.
Аның сөенеп уйнавы
Әнә шуны аңлата[33:7].

Бикә Рәхимованың "Шәһәрдә атка утырып мәктәпкә бару"шигырендәге герой үзенең атка утыруы белән горурлана,шатлыгы эчен сыймый.

Мәктәпкә барганда,
Атка утырттылар!
Шатлыгым сөйләсәм,
Бөтен дөнья тыңлар[29:49],-ди.

Галимҗан Гыйльманов "Хыял-ат" һәм Резедә Вәлиеваның "Атым-минем канатым" шигырьләрендә малайлар хыялларын ат иткәннәр.Алар шул атка утырып әбиләре янына кайтып киләләр,айга,йолдызларга менәләр.

Айга барып киләбез,
Болытларга менәбез дә
Җиргә карап көләбез[12:10]....

"Акбүз ат" шигырендә малайга әтисе ат алып биргән.Малай болай ди:

"Ә" дигәнче акбүземә
Менеп атландым.
Тояк тавышлары гына
Яңгырап калды.[7:56].....

Нәҗип Мадьяров "Колынлы ат" шигырендә атның үз баласын ничек итеп яклавын бик зур осталык белән сурәтләп биргән.

Кагыласы булма,диптер,
Минем таема,
Колакларын тырпайта ул,
Барсаң янына[29:63].

"Йөк аты"шигырендә Гүзәл Исхакова атның кеше сыман уйлануларын тасвирлап бирелгән.

Иртән торгач,бар ашыйсы,
Амбарга солы ташыйсы[18:27].

Эш аты турында Рафис Корбан да кызыклы шигырьләр язган.

Атлар да җил белән куышып уйнарга яраталар икән моны “Аткаем” шигыре белән Флера Тарханова исбатлап күрсәткән.

Ак аткаем,туп-туры итеп,
Җилне тотам дип чаба,
Ә җил кинәт борылып исә
Ак аткаема таба[34:15].

Гөлшат Зәйнашева “Ат кирәк безгә” дип үзенең теләген белдерә.Ат булса,җәй көне ат чабыштырып уйнар идек ,ди. Роберт Миңнуллинның геройлары “Бахбай”ны абзардан чыгарыргамы,чыгармаскамы дип баш ваталар.Ахырдан мондый нәтиҗәгә киләләр: чыгармыйк әле, я тешләр диләр. Р.Мингалимнең «Атланабыз атларга» дигән шигырендә малайлар үзләренең атка атланып чаба алулары белән горурланалар. Чөнки атка атланып йөрү—малайларның хыялы ул. Ат — халкыбызның тәрбиячесе. Безнең төрки-татарның табигыйдан иҗтимагый кешегә әверелүендә Атның роле, һичшиксез, бар һәм ул кечкенә түгел.. Утрак тормышта яшәгән халыкка ат-йөк ташучы, җир эшкәртү коралы булып, күчмә тормышта яшәгәннәргә ул транспорт булып күбрәк файдаланыла.

Борын-борын заманда ук кеше атны йөгәнләү-ияләштерү әмәлен тапкан. Кеше атсыз яши алмый, ат — ат инде ул. Борынгы заманнан ук ат кешенең тормышын бизәгән.

Менә шушы темаларны Нур Әхмәдиев “Атларым, колыннарым”,Ләлә Гыймадиева “Яшь тай”,Габдулла Галиев “Атлар да елый икән”, Гомәр Бәширов “Туган ягым-яшел бишек”,Фаил Шәфигуллин “Бер малай,өч аргамак”,Мәгъсүм Хуҗин “Курагай атлары”дигән әсәрләрендә чагылдырганнар.

Башын дугага бәреп селтәп, эре адымнары белән тузан чәчрәтеп кайта Соры бия. Атның шулай урамны бизәве төш турында — җете кояш чагында күңелне аеруча шатландыра: эштән кайта торган атың арымаган, аның җир куптарырлык көче бар; төшке ашка кайтучы кешеләрнең сокланып каравыннан ат та сөенә.

Шундый горур кыяфәт белән атлар кешеләрне сабантуй мәйданына алып барырга, печән ,өстендә җырлы болынга алып төшәргә һәм бәхетле йортка уңган килен алып кайтырга яраталар. Менә Соры бия... Мин җиккән ат... Урамны балкыта Соры бия [40:110]...

Сугыш елларында да атлар авыл халкының төп таянычы булганнар.

Без Арчадан награин дигән -ягулык алып кайтабыз. Көч-хәл белән ун-унике чакрым ара үттек, Курса авылын атларга булыша-булыша үрләдек. Башка чакта без авыл урамнарын йөк төяп тә юыртып уза идек — күрсеннәр безнең Курагай атларын! Бүген атларның борын тишекләре йодрык сыярдай ачылган,
тәннәреннән пар күтәрелә – өсләренә яуган кар эри бара. Үзебез дә көчкә атлыйбыз[40:110].

Фаил Шәфигуллинның “Бер малай өч аргамак”повестендә дүртенче класста укучы Рәсим исемле малайның ат белән ашлык урырга баруы. Төрле авырлыкларга очравы.Ләкин авырлыкларга очраса да, шатлыклы мизгелләр кичерүе турында бара.

Шулай да иң күңеллесе — берүзең өч ат белән урактан кайту. Бөтен кешенең күзе синдә. Ә син ике яктан йокымсырап кайткан атларыңа аны-моны сиздерми генә тезген очы белән чирткәләп аласың. Атлар, сискәнеп, башларын күтәрәләр, авызларыннан ут чәчеп торган ак яллы аргамаклар кебек, кырын-кырын атлап китәләр, колакларын шәмрәйтәләр. Ә син, аларга бөртек тә игътибар итмәгәндәй, уртадагы атыңа атланган көе, сыныңны туры тотып, юл уртасыннан узасың [42:81].

Гомәр Бәшировның “Туган ягым-яшел бишек”әсәрендә ат белән җир эшкәртү вакыты сурәтләнгән:

Әти алдан чәчеп бара, мин аның артыннан тырмалап барам. Әлеге шул бер күзе «өшегән» кара бия, башын чайкый-чайкый, бәкәленнән туфрак ерып атлый. Ат артыннан, җир өстенә буйдан-буйга дымсу эз калдырып, тимер тешле агач тырма сөйрәлә [5:218].

Габдулла Галиевның “Атлар да елый икән” хикәясендә ундүрт-унбиш яшьләр тирәсендәге Рәсим белән Галигә район үзәгеннән ике йөзәр сыешлы керосин мичкәләре төяп алып кайтырга ат бирәләр.Көн бозылып китү сәбәпле алар юлны бик акрын үтәләр.Атларны ашатырга ризыклары да калмый.Малайлар атларны ял иттерә-иттерә икенче көнне генә

кайтып җитәләр.Бригадир бик ачуланып каршы ала.Һәм керосинны басудагы тракторларга алып барырга куша.Арган атлар белән үргә таба менәргә була.Ат арганлыктан туктап кала.Гали ачудан Карлыгачын кыйный башлый.Карлыгачның үзәк өзгеч җан авазы белән ыңгырашуыннан гына айнып китә.Гали,туп кебек атылып,Карлыгачы янына килде һәм аңа тезләнгән,тора алмыйча газапланган җиреннән аякларына басарга булышты, аннан муенынна  кочып алды да кычкырып елап җибәрде: «Карлыгачым!.. Җаным!.. Гафу ит мине?! Зинһар, гафу ит... Кабахәт малай мин... миһербансыз малай... Сиңа суккан кулым корысын! Яшен суксын мине! Зинһар, гафу ит мине, Карлыгачым!» Гөнаһсыз хайван, хуҗасының күз яшенә тыгылып әйткән сүзләрен аңлаган кебек, башын Галинең күкрәгенә терәде. Атның күзләрендә эре яшь бөртекләре күреп, Гали тетрәнеп китте, бәгыре телгәләнде. Аңа кушылып, Карлыгач та елый иде [9: 62-63 б].

Сугыш елларында атларда солдатлар булып сугыш юлларын үттеләр.Безгә моны Ф.Кәримнең “Пионерка Гөлчәчәккә хат”, М.Җәлилнең “Сандугач һәм Чишмә”, М.Хәсәновның “Җирән кашка”, Мин Шабайның”Җирән кашка”әсәрләре дәлил булып тора.

Ниндидер язу, хат килгән дипме шунда, бабамны колхоз идарәсенә чакырдылар. Кылый Хәлим безне сары тешләрен күрсәтеп елмаеп каршы алды.

- Ну, Шәйми абзый, үзең дә атны тәрбияләгән икән. Менә укы, Каракүзең турында язганнар.

Кочубин исемле яраланган кавалерист командирдан  икән.  «Үземнең исән  калуым белән дә бары тик Каракүзегезгә  гына бурычлымын», дигән.  Каракүз  аны  сугыш кырыннан алып чыккан икән.

Кочубин Каракүзнең бик җитез, тапкыр, гаять акыллы булуы турында язган [39: 139].

Сугыштан яраланып кайтучы Мәүлит абый ат турында болай ди:

Ат уйлый ул. Уйламый, дисеңме? Уйлый туганым. Чабышта Җирән айгырның бөтен уе, мәйдан уртасына ярып кереп, муенына киҗеле сөлге бәйләтү була иде. Кешеләр, сабантуйның яме мин,— дип мактана иде ул. Мәйдан уртасына беренче булып кергән чабыш атының өстендә килүнең рәхәтлеген белсәң икән син, Дуслай энем... Сабантуйда ат чабышы дөньяны бәхеткә төргән изгелек бит  ул... Хәзер генә Җирән айгыр бетереште, сугыш җәфасы тиде. Сабантуйда күрше-тирәгә дан таратып мәйдан гөрләтә идек без аның белән...

Җирән айгыр үзгәргән иде. Хәтта аның төкләре дә агарган, элеккеге ; елгырлыгын җуйган, адымнарында элеккеге елгырлыгы юк – сугыш изгән аны. Ә бит Җирән айгыр, Мәүлет абый иярләп барганда, ике якка салынып төшкән озын калын ялларын уйнатып, бөтен урамга хуҗа булып уза иде, бала-чага, атны җигәргә өйрәткән чактагы кебек, койма буена, киртә артына поса иде. Хәзер, әнә, Җирән айгыр башын салган, яллары тузан себерә.

— Сагынды Җирән айгыр туган җирен,- диде Мәүлет абый кесәсеннән шикәр кыйпылчыклары алыш Җирән айгырга каптырды [40:115].

Әйе, атлар да туган җирен сагына икән Габделхәй Сабитов “Айбаш”ы нигезендә моны дәлилләргә була. Малайлар Галәү бабай белән ат котәргә чыгалар. Шунда бабай аларга менә мондый хикәя сөйли: “Безнең ат бар иде, ләкин бурычны түли алмаган өчен алып чыгып киттеләр. Менә шул атның колынын кулдан ашатып үстердем. Маңгаенда яңа туган айга охшаган кашкасы да бар иде. Шуңа карап исемен Айбаш дип куштык. Озак та тормый тагын атсыз калдык. Йорт –җиребез янды, атны Себер баена сатарга туры килде. Ярты еллап вакыт үткәч, байдан хат килде, атның югалуы турында. Шуннан соң ел ярым үткәч, атыбыз сөяк белән тирегә генә калып кайтып керде. Янына килдем. Таныды хайванкай! Элеккечә башын җилкәмә салды да йокыга киткән кебек,  бик озак торды. Өйгә кереп, икмәк кисәкләре алып чыктым, ашамады. Алдына  солы салдым, иснәп тә карамады. Икенче көнне, иртән торып чыкканда, үлгән иде инде мескенем! Башын салкын көл-күмер өеме өстенә салган, авызыннан ямь-яшел сарут бөртекләре күренеп тора. Туган җирдә үскән шул бер учма үләнне эзләп кайткан диярсең...

Галәү бабай озак кына сүзсез торганнан соң, тирән сулап, барлык сөйләгәннәренә йомгак ясаган кебек итеп әйтеп куйды:

— Кадерле ул туган як. Кешегә генә түгел, хайванга да изге ул туган җир туфрагы [31:13-14].

Н. Арсланның «Акбүз ат» хикәясендә атларны төрле җирдән җыеп ябып куюлары турында сүз бара. Араларында бик матур акбүз ат була. Аның күзләре бик сагышлы. Ул туган җирен сагына, кая барырга белми. Кинәт ул койма аша сикерә дә, елганы йөзеп чыгып, даласына таба чабып китә һәм үз иленә кайта. Хикәяне укыгач, атларга да туган җирләре якын икәнне белдем мин.

Илдар Низамов үзенең балачагын сагынуын атларга бәйле рәвештә искә ала:

Бар иде дуамал яшь тайның муенына ук сарылып,аның кая барып бәреләсен дә белмичә, болай гына — тормыш белән күзгә-күз карашудан, тәүге мәхәббәтнең тылсымлы ләззәтеннән яшь йөрәкнең шашып тибүен басар өчен генә, болын-тугайлар буйлап чапкан чаклар.

Бар иде әле буыннар да ныгып җитмәгән килеш атлар белән бергә тәртәгә җигелеп, урманнан бүрәнә чыгарган, тракторларга керосин ташыган чаклар...

---

Бар иде сабан туйларында: «Атлар килә!» — дигәч, мәйдан читенә атылып чыгып, уктай томырылып килгән чаптардан күзне ала алмыйча сихерләнеп торган чаклар.

Бар иде урман белән басуны тоташтырган тар гына юлдан җиз кыңгырау моңын, чикләвек куакларының өлгереп килгән арыш белән сөйләшеп кыштырдавын тыңлый-тыңлый, яңа чабып салган печән өстендә аякларны салындырып бала-чага белән кунакка барулар...Бар иде... атлар интеккән, алар белән беррәттән кешеләр интеккән авыр чаклар.

Онытылсын алары, мәңге кире кайтмасын. Әмма ат биргән, ат белән бергә күргән сөенеч-куанычлар да бар иде. Атларны нигә онытырга? [28:156] – ди “Атлар килә”дигән парчасында.

Р.Гаффарның «Мине йолдызлардан эзләгез» хикәясе хәтта елатты да, чөнки ул бик кызганыч итеп язылган.

Хикәядә Әленәк авылының зәңгәр күзле акбүз аты турында сөйләнә. Ул Сабан туенда чабышларда катнаша торган була. Аны бик яраталар: аңа атланып йөриләр, арбасына утыралар, аны сыйлыйлар. Ул 7 ел чабышта җиңүче була.

Ләкин бу юлы акбүз атның бер дә чабышка барасы килми. Колынын калдырудан курка ул. Рәхәтләнеп болында йөргәндә, аны кыйный-кыйный алып китәләр.

Ярышка кузгалгач, хуҗасы аны типкәли. Менә ул алдагы атны да куып җитә. Ә аның өстендә – былтыр арбасына утыртып, больницага илткән малай. Малайның аны уздырасы килми һәм ул чыбыркы белән акбүз атның күзенә суга. Ат сөрлегеп китә, өстендәге малай җиргә мәтәлә. Малай ташка төшмәсен дип, ат аның астына мәтәлә һәм үлә.

Хикәя үлгән ат исеменнән булгач, бигрәк тә кызгандыра. Ат күзенә суккан малайның бик начар күңелле булуы нәфрәт уята. Аның аркасында нәни колын ятим кала.

Ләлә Гыймадиеваның “Яшь тай”әсәрендә Хәлим исемле малайның печән җыюда үзеннән өлеш кертү әйтелгән.

Мишәдә ат йөздергәнегез юкмы сезнең? Минем бар. Күк алашаны йөздерергә ятатам мин. Суда сөлеккә әйләнә ул. Өстенә атланасың да, елганың уртасыннан— Кәкре тугайдан башлап тегермән буасына хәтле йөздерәсең. Күк алашаның башы судан шуып кына бара, ә син атны борчымыйча, аякларыңны тездән бөгеп, атның корсагына саласың — аңа йөзәргә комачауламаска кирәк. Ике колак арасыннан сөеп куясың — Күк алаша тагын да тизрәк йөзә [40:110].

Язучылар атларны мактап кына калмаганнар аларның кирелекләрен укучыларга җиткерергә теләгәнннәр. Менә Л.Леронның «Киребеткән» хикәясендә сүз. Әнисен тыңламаучы кире колын турында бара.

---

Фәнис Яруллинның “Юылмас хурлык”әкиятендәге ат үзенең көче белән мактана,ләкин әнисенә бүреләр ташлангач куркып кала.Шуның аркасында әнисен югалта.

— Әнкәм, әнкәм,— дигән Колын, — мин ант итәм: явызлардан куркып калмам бүтән. Ташланырмын утка-суга, давылларга. Беркемне дә рәнҗеттермәм җаным барда. Һәм

сүзендә торган Колын, батыр булган. Бик гайрәтле көтү башы айгыр булган. Саклаган ул ат көтүен һәр ерткычтан. Күзе аның очлы булган бөркет-коштан. Күкрәгендә арыслан көче булган. Әгәр типсә, дәү имәннәр шартлап сынган. Көтүлеккә ерткыч бүреләр килмәгән. Ул барында беркем дә курку белмәгән[43:25].

Ә Л.Леронның «На-а, бахбай» хикәясендә велосипедка атланган малай «сә-пите»нә: «На-а, бахбай» — ди. Чөнки хәзер инде атлар бик аз. Без аларны авылларда гына күрәбез. Ә малай үзен атта чапкан шикелле тоя. Аңа күңелле.

Г.Ибраһимов,Р.Мөхәммәдиев,Мәхмүт Хәсәнов,Нур Әхмәдиев кебек язучылар атларның матурлыгын сурәтләүдә төрле алымнар кулланганнар .
Колын чыннан гаҗәеп бер нәрсә иде.

Аның ботлары ничектер җиңел атлыйлар. Бәкәлләре озын, шундый нечкә-озын ки, мондыйлар тик чабышкы атларда гына була, диләр. Әле яңа гына кибеп килә торган койрыгы белән ялы, әз генә, кыска тына булсалар да, озаклап үреп, кабартып ясаган ефәк бәйләме кебек үзеннән-үзе дулкынланып торалар. Түм-түгәрәк сырты өстеннән, нәкъ арка үзәк турыннан, бармак калынлыгы кара тасма кебек булып, койрыктан ялга җиткәнче, кара ефәк йон сузылган. Озынча, акыллы башның киң маңгаендагы озын яра кашка — бу колынны мең миллион иптәшләре арасыннан бөтенләй аерып, матурлыгы белән ялгыз итеп күрсәтәләр. Бөтен гәүдәсе, әйтерсең, ходайның үз кулы белән, фәрештәләрнең ярдәме белән тигезләп, матур итеп, коелып ясалган. Шундый сылу, шундый асыл сөяк булып яратылган [17:22].

---

Алмачуарым бу арада карап туйгысыз булып чибәрләнде. Ял, койрык ефәкләнеп, дулкынланып тора. Эч, каеш белән тарттырган кебек, нечкәреп, тип-тигез булып эчкә керде. Буе тагы да озыная төшкән кебек күренә. Аяк атлаулары шундый җиңел инде, әйтерсең ул җиргә басмый, бәлки, күзгә күренми торган канатлары белән очып кына бара [17:23] .

Күк биядән күзләремне алмадым. Гаҗәп бер мал икән: кыска яллы, сирәк койрыклы, чандыр гәүдәле нәрсә. Очасы тар, бер якка бераз чалыш, аркасы бераз бөкрерәк. Әмма күкрәк — бөтенләй арысланныкы: шундый киң, шундый нык күренә. Тезләре ике яккарак китеп тора, бәкәлләренә карагач, тагы хәйран калдым: алар шундый озыннар ки, мин гомеремдә андыйны күргәнем юк. Күзләре зурлар,— уйнап, ялкынланып торалар [17:36,41].

Озын сыйраклары бер атлаганда ким дигәндә тәртә буе җир алдыра иде. Каеш белән кысылып килгәндәй ялтырап торган тыгыз билләре дисеңме, канат сыман җилдә җилфердәгән ялларымы, сыртының дәвамы сыман дугайланып үрә баскан койрыкмы — Чемпионның исеме генә түгел,килеш-килбәте,һәр хәрәкәте дә мәһабәт иде [27:6] .

Атларның да нindiләре генә юк: шомырт-кара турылар, әкияттәге кебек җете аклар, сырт һәм савырларына чиләк-чиләк «алма» тәгәрәгән алмачуарлар, янә дә башны күккә чөеп әледән-әле кешнәп җибәргән йолдызлы кашкалар да [27:10]...

Шулай да табигать моны чабыш өчен яратканы күренә. Бергә кушыла төшкән нәзек аяклар дисеңме, кыршау кидерелгәндәй түгәрәк нечкә билме, калку киң күкрәк һәм озынча муен— һәммәсе чабыш өчен [27:12].

Елгыр биянең сабырлыгы, түземе җитмәде ахры—көтмәгәндә, башын югары чөеп, кешнәп җибәрде. Аның кешнәү авазы шундый саф һәм эчкерсез иде, нигә тиңләргә дә белгән юк. Айлы кичтә вак ташлар өстеннән чылтырап аккан чишмә тавышын да, гөнаһсыз сабый баланың кычкырып көлгәнен дә, буй җиткән кыз чәчләрендә чылтырашкан чулпылар чыңын да хәтерләтә сыман ул. Кола бия әнә шулай тагын һәм тагын кешнәде[27:20]. .

Бәбәй иллә дә эре гәүдәле, киң маңгайлы аккош күргәнегез бардыр, аккошныкы төсле текә муенлы, озынча гәүдәле җан иясе иде. Чем-кара төстә иде. Чистартып җибәрсәң, сырты хром итек кебек елтырап тора башлый иде [2:70].

Күзем кашка маңгайлы, ак бәкәлле, киң күкрәгенә озын ялы таралган алмачуар төстәге мәһабәт айгырга төште. Гәүдәгә дә тау кадәр. Алып барда куәт бар, ди халык. Гайрәте ташып тора [2:93].

Катрин искиткеч. Сөт өсте төсле ап-ак.Ул бар гәүдәсе белән сузылып-сузылып чаба.Аяклары җиргә тиядерме,әллә аны нindiдер сихри көч очыртып йөртәме-билгесез.Ул

атлатлап өйрүләре,ул башларын горур тотулары! Әллә кайдан, күрәсезме,менә без кем, дип кычкырып торалар.Аксөяк,затлы сөяк [2:100].

Казбекның кап-кара маңгай чәче, салынып торган яллары аның җиз тәңкәле йөгән кидерелгән зур башын бигрәк тә мәһабәт итеп күрсәтә [2:26].

Ат дәвалау чарасы да,хыялны да яшәтүче өметтә булган.Р.Төхвәтуллинның “Акбүз ат” әсәрендә Галимҗан исемле малайга әтисе авырып ятканда Акбүз ат турында әкият сөйли.Шушы әкият малайны аягына бастыра.Һәм гомере буе озата бара. Галимҗан иптәше Хариска да сөйли. Сугышта Галимҗан үлеп кала.Харис сугыштан исән-имин кайта һәм Галимҗанның малае Әсгатькә Акбүз ат турындагы әкиятне сөйли. Әсгать тракторны да минем Акбүз атым дип йөри башлый. Акбүз ат аның хыялында үсә.

Өстәлдә металлдан коеп ясалган зифа ат сыны пәйда булды. Озын-ыспай аякларының ашкынулы бөгелешләренә, ял-койрыгының җилдә җилфердәгәндәй дугай- дугай күпереп торуларына караганда, аргамак менә-менә өстәл буйлап, бүлмә буйлап очып кына чабып китәр төсле иде.

— Акбүз ат бу, әни. Харис абыйга истәлегем,— диде Әсгать, илһамлы елмаеп.— Күптән койган идем дә, игәләп-шомарткалап «җан кертергә» һаман кул тими ятты. Калган эшкә кар яуды. Бүген инде бетерми кайтмыйм дип тотындым. Моннан ары бер генә эшебезгә дә кар яумасын, Харис абый. Юкса... юкса, Акбүздән егылып төшүебез дә бик ихтимал [35:70].

Атның яхшы сыйфатлары һәм бигрәк тә көче, чисталыгы күп булганга,халкыбызда атка ихтирам зур.Шуңа күрә дә хатыннар үзләренең ирләрен “ат” сыйфаты кушып,дәрәҗәсен күтәреп”ир-ат”,диләр. Кырык дүрттән артык хикәя һәм шигырь анализлау нигезендә, безнең тарафтан түбәндәгеләр ачыкланды:

1. Язучыларыбыз күп кенә әсәрләрен Атка мәдхия җырлап язганнар.
2. Халкыбыз атларны төрле эшләрдә (хуҗалык көнкүреш ихтыяҗларында) файдаланган;
3. гаскәрдә, элемтә-хәбәр йөртүләрдә;
4. хайваннар белән бәйле төрле уеннар да(Сабантуй да ат чабышы,ат спорты);
5. колынны балачак белән чагыштыру;
6. ат образы шаян формада бирелә(велосипед,мотоцикл);
7. ат образын авылларның киләчәген күрсәтү өчен тасвирлый
8. ир-атларны ат белән чагыштыру

Мөхтәрәм язучы Мөхәммәт Мәһдиев үзенең күп кенә әсәрләрендә атка мәдхия җырлый, авылны саклап калырга теләсәк, иң беренче чиратта атларны саклап калырга кирәк дигән фикерне алга сөрә.Бүгенге югары технологияләр, компьютер, космос заманында аның бу фикере кайберәүләргә сәер тоелырга мөмкин. Әмма берничә сәгать эчендә бер кыйтгадан икенчесенә барып җитүче реактив самолетларның да, машина-тракторларның да егәрлеге әле бүген дә ат көче белән исәпләнүен онытмыйк.

*Кулланылган әдәбият:*

1.Әгъләмов Мөдәррис.Мин әйттем. Шигырьләр.- Казан:Татарстан китап нәшрияты,1991.-208 б.

2.Әхмәдиев Нур.Атларым,колыннарым.Повестьлар,хикәяләр. -Казан:Татарстан китап нәшрияты,1997.-192 б.

3.Батталов Ринат.Гомер учагы.Шигырьләр. - Казан:Татарстан китап нәшрияты,2008.-143 б.

4.Бәшәр Рәшит.Кояшлы яңгыр.Шигырьләр.-Казан:Мәгариф,2003.-47 б

5.Бәширов Гомәр.Туган ягым-яшел бишек.Сайланма әсәрләр III том.-Казан.Татарстан китап нәшрияты 1968.-436 б.

6.Бикчәнтәева Әминә.Сайланма әсәрләр.- Казан:Татарстан китап нәшрияты,1963.-216 б.

7.Вәлиева Резедә.Мыраубикә малае.Шигырьләр,җырлар,поэма.- Казан:Татарстан китап нәшрияты,2000.-128 б.

8.Гайсин Нур.Яңа өйгә күчкәч.Сайланма шигырьләр,әкиятләр һәм поэмалар. - Казан:Татарстан китап нәшрияты,1969.-184 б.

9.Галиев Габдулла.Кичер мине,Сурия.Хикәяләр. – Казан:Татарстан китап нәшрияты,1997.- 78б

10.Галиев Шәүкәт.Шәвәли хәйләсе. Шигырьләр.- Казан:Татарстан китап нәшрияты,1998.-256б.

11.Гафиятов Атлас.Атларны кем яклар?Татарстан яшьләре.№ 60,17 ноябрь,2011ел,7 б.

12.Гыйльманов Галимҗан.Әбием сихерче бугай.Нәниләр өчен шигырьләр. Казан:Матбугат йорты нәшрияты,1999.-160 б.

13.Гыймадиева Ләлә.Мин аңа бәхет телим.Хикәяләр,повесть.- Казан:Татарстан китап нәшрияты,2007.- 135 б

14.Җәлил Муса.Сандугач һәм Чишмә.Баллада.- Казан:Татарстан китап нәшрияты,1985.- 15 б

15.Җәләлов Хәлим.Корчаңгы тай һәм Таз малай.Әкият. - Казан:Татарстан китап нәшрияты,1994.-32 б.

16.Зәйнашева Гөлшат.Әбиемне яратам.Шигырьләр,җырлар.- Казан:Татарстан китап нәшрияты,1997.-55 б.

17.Ибраһимов Галимҗан.Алмачуар.Хикәя. .- Казан:Татарстан китап нәшрияты,1990.-47 б

18.Исхакова Гүзәл.Сөенеч.Әкиятләр.- Казан:Татарстан китап нәшрияты,2005.-32 б.

19.Кәрим Фатих. Пионерка Гөлчәчәккә хат.- Казан:Татарстан китап нәшрияты,1975.-30 б

20.Корбан Рафис. Минем туган көнемдә. Шигырьләр, табышмаклар,тәрҗемәләр. - Казан:Татарстан китап нәшрияты,2007.-96 б

21.Лерон Ләбиб.Кояшны кочкан малай. Шигырьләр, җырлар, әкиятләр, мәзәкиятләр, шигъри әкиятләр,әкият-пьесалар. -Казан:Мәгариф,2004-303 б.

22.Ливанова Татьяна.Рядом с лошадью.-Казань:Татарское кн.изд-во,1999.-231 б.

23.Мадьяр Нәҗип.Әкәмәт. Балалар өчен шигырьләр.- Казан:Татарстан китап нәшрияты,2008.-112 б.

24.Мәһдиев Мөхәммәт.Ачы тәҗрибә.Истәлекләр.- Казан:Татарстан китап нәшрияты,1993.-384 б.

25.Мәһдиев Мөхәммәт.Кеше китә-җыры кала.Повестьлар,истәлекләр,хатлар.- Казан:Татар китабы,1996.-288 б

26.Миңнуллин Роберт.Тәмлетамаклар. Балалар өчен шигырьләр.-Казан:Матбугат йорты нәшрияты,1998.-20 б.

27. Мөхәммәдиев Ринат. Ат чабышы. Хикәя.- Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1992.- 20 б.

28.Низамов Илдар. Өмет.Повесть,хикәяләр,парчалар.- Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1977.-191 б

29.Рәхимова Бикә.Җайдак малай.Шигырьләр. Казан:Мәгариф,2007.-103 б.

30.Рәхим Гәрәй.Тимер торна.Шигырьләр.- Казан:Татарстан китап нәшрияты,1993.-48 б.

31.Сабитов Габделхәй. Кайнар туфрак:Хикәяләр.-Казан :Татар. кит. нәшр., 2001.- 160 б

32.Салават күпере,1999,№ 5-6

33.Сафин Фәннур.Яңгыр малае. Шигырьләр,әкият-фаҗига.- Казан:Татарстан китап нәшрияты,1993.-63 б.

34.Тарханова Флера.Серле дөнья.Балалар өчен шигырьләр. - Казан:Татарстан китап нәшрияты,2002.-40 б

35.Төхвәтуллин Рафаил.Акбүз ат.Хикәяләр. - Казан:Татарстан китап нәшрияты,1977.- 184 б

36.Тукай Габдулла.Шигырьләр,әкиятләр,поэмалар.-Казан Татарстан китап нәшрияты.1990.-255б.

37.Халикова.Р.Ш.Раушан көзге.Татар балалар әдәбиятыннан хрестоматия:Педагогия училищеларының мәктәпкәчә яшьтәге балаларны тәрбияләү бүлеге өчен кулланма. Казан:Мәгариф,1993.-255 б.

38.Хәлим Айдар.Өч аяклы ат.Повесть. - Казан:Татарстан китап нәшрияты,1998.-143 б.

39.Хәсәнов Мәхмүт. Урман шаулый. Повестьлар,хикәяләр. – Казан: Татарстан китап нәшрияты,1977.-192 б

40.Хуҗин Мәгъсүм. Карагай атлары.Хикәяләр. – Казан:Татарстан китап нәшрияты,1973.-152б

41.Шабай Мин. Уйналмаган скрипка.Повесть,хикәяләр.- Казан: Татарстан китап нәшрияты,1977.-287 б

42.Шафигуллин Фаил.Бер малай,өч аргамак. Повестьлар,хикәяләр. - Казан:Татарстан китап нәшрияты,2005.-272 б.

43.Яруллин Фәнис.Биюче бака.Әкиятләр. -Казан:Мәгариф,1996.-104 б

## ТАТАР ХАЛЫК МӘКАЛЬЛӘРЕНДӘ ИКЕ САНЫНЫҢ СЕМАНТИК ТӨРКЕМНӘРЕ

*Шарапова Йолдыз, 2 курс студенты,*
*Фәнни җитәкче– Гайнуллина Гөлназ Фоатовна,*
*филология фәннәре кандидаты, доцент*
*Казан Федераль Университеты*

***Резюме.*** *Мәкалә татар халык мәкальләрендә урын алган ике санының семантикасын ачыклауга багышланган. Ике санының татар халык мәкальләре контекстында семантик төсмерләре ачыклана. Теге яки бу семантиканы тудырырга ярдәм иткән чаралар анализлана, семантик төркемнәр бүленеп чыгарыла.*

***Ачкыч сүзләр:*** *семантика, татар халык мәкальләре, ике, семантик төркемнәр.*

Мәкальләрнең күбесендә сан сүз төркеме кергән үрнәкләргә тап булырга мөмкин. Сан сүз төркемеен мәкальләр контекстында өйрәнү зур кызыксыну уята, чөнки саннар мәкальләрдә урын алган вакытта яңа семантик мәгънәгә ия булалар. Саннарның семантикасы мәкальләрдә төрле төсмерләр ала. Шул рәвешле саннарны хәтта төрле семантик төркемнәргә дә аерырга мөмкин.

Олуг фольклорчы Нәкый Исәнбәтнең “Татар халык мәкальләре” өч томлыгында сан сүз төркеме кергән мәкальләргә күз салганда, берникадәр статистик мәгълүмат тупларга мөмкин. Өлкән әдибебез Нәкый Исәнбәтнең әлеге хезмәтен татар халык авыз иҗаты өлкәсендә фәнни хезмәтләрнең энҗе-мәрҗәне.

Тикшеренүләрдән чыгып, мәкальләрдә очраган саннарның кулланылыш активлыгы санап чыгарылды. Нәтиҗәләр игътибарга лаеклы. Куланылыш буенча беренче урында *бер* саны тора. Ул мәкальләрдә 1577 мәртәбә кулланылган, аннан соң *ике* саны бара- 629. *Өч*- 127, *дүрт*- 43, *биш*- 91, *алты*- 109, *җиде*- 96, *сигез*- 49, *тугыз*- 55 тапкыр очрый. *Ун* саны- 128, *егерме*- 32, *утыз*- 47, *кырык*- 118, *илле*- 49, *алтмыш*- 61, *җитмеш*- 28, *сиксән*- 30, *туксан*- 24, *йөз*- 74, *мең*- 105, *төмән*-1, *миллион*- 1 мәртәбә күзәтелә.

*Ике* санына килгәндә, кулланылыш буенча ул *бер* саныннан соң икенче урында тора. Әйтергә кирәк, еш кына анализланган мәкальләрдә *ике* саны *бер* саны белән бергә килә. Мондый төр мисалларда *ике* саны һәрвакытта *бер* санына капма- каршы куела. Шул рәвешле, *ике* һәм *бер* саннары мәкальләрнең семантикасын бергә тудыралар. Ягъни мондый мисалларда, *бер* һәм *ике* саннары төрле семантикага ия түгел, киресенчә, аларның семантик вазифалары бергә үрелеп, яңа семантик төркем барлыкка килүгә этәргеч булып тора.

*Ике* саны кергән беренче семантик төркемгә “Ялкаулык” исеме бирелде.

*Иренгән-* ***ике*** *үләр [И.Н. Тат.хал.мәк.т.1: 328]*

*Иренгән-* ***ике*** *утырыр, итәген чүпкә тутырыр [И.Н. Тат.хал.мәк.т.1: 329]*

Китерелгән барлык мисалларда да *ике* саны лексик- грамматик төркемчә ягыннан микъдар санына керә. Өстәмә кушымчалар алмаган рәвештә, *ике* саны беренче мисалда исемне ачыклап килә, калган мисалларда исә фигыль сүз төркемен ачыклый. Шулай итеп, *ике* саны эшнең үтәлү процессының ничә мәртәбә кабатланганлыгын белдерә. Хәрәкәт фигыльләре (*эшләр, утырыр, тутырыр*) *ике* санына ялкаулык семантикасын тудырырга ярдәм итә. Эш процессы *ике* саны ярдәмендә ялкаулыкка, бер эш тә эшләмәүгә каршы куела. Шуны да искәртеп үтергә кирәк, әлеге мисалларда зур рольне паралингвистик чаралардан- көттерү паузасы уйный. Пауза ярдәмендә (язма сөйләмдә ул тире ярдәмендә бирелә) *ике* санына синтагма басымы йөкләнә. Мәкальләр тискәре коннотациягә ия.

Икенче семантик төркем, "Капма-каршылык" төркеме, *ике* саны белән *бер* саны каршылыгы нәтиҗәсендә барлыкка килгән мәкальләрне үз эченә туплый.

*Бер санаганны* ***ике*** *санасаң, шайтан көләр [И.Н. Тат.хал.мәк.т.1: 392]*

***Ике****-бер исәп [И.Н. Тат.хал.мәк.т.1: 393]*

***Ике*** *исәп- бер исәп, бер исәп- юк исәп. [И.Н. Тат.хал.мәк.т.1: 393]*

***Ике*** *бер иткән, берне юк иткән [И.Н. Тат.хал.мәк.т.1: 393]*

*Ике* саны белән *бер* саны мисалларда үзара чагыштырылалар, һәм, нәтиҗәдә, капма-каршылык семантикасы туа. Беренче мисалда *бер* саны билгесезлек алмашлыгы вазифасын үтәп, билгесезлек артикле буларак кулланылган. *Ике*- микъдар санына керә. Икенче һәм өченче мисалларда *бер* һәм *ике*- шулай ук микъдар саннары. Өченче мисалда капма-каршылык семантикасын тудыруда паралингвистик чара- көттерү паузасы зур роль уйный. Өстәвенә, бу мәкаль ике компоненттан тора. Бу шулай ук *бер* һәм *ике* саннарының үзара чагыштырылуына этәрә. Соңгы мисалда *бер* саны исемләшеп, исем сүз төркеменә хас булган грамматик категорияне- килешне үзләштерә. *Ике* саны бер санына каршы куелып, күләме ягыннан гына түгел, ә семантик көче ягыннан да зуррак булып чыга. Чөнки *бер* саны белән чагыштырганда, ул аны хәтта "юк итәргә" дә сәләтле.

Өченче семантик төркем- "Бердәмлек".

***Ике*** *сәкыйм- бер Мөстәкыйм [И.Н. Тат.хал.мәк.т.1: 393]*

***Ике*** *арада, бер турыда [И.Н. Тат.хал.мәк.т.1: 396]*

*Юк белән бар* ***икесе*** *дә бер [И.Н. Тат.хал.мәк.т.1: 402]*

*Бака- елан бер телдә,* ***икесе*** *дә бер күлдә [И.Н. Тат.хал.мәк.т.1: 561]*

Алда анализланган семантик төркемдәге кебек үк, биредә *бер* һәм *ике* саннары анализлана. Ләкин алар инде яңа семантик төсмер- бердәмлек семантикасын тудыра. Беренче ике мисалда *ике* һәм *бер* микъдар саны лексик- грамматик төркемчәсенә керә, исем һәм бәйлек сүзләрен ачыклый, раслау пафосы ярдәмендә бердәмлек семантикасын тудыра. Өченче мисалда *ике* саны исемләшү нәтиҗәсендә, тартым грамматик категориясен үзләштерә. Ул өченче зат берлектәге –се кушымчасы ярдәмендә формалашкан. *Юк* белән *бар* чагыштырылып, аларның бер үк әйбер булганлыгына басым ясала. Ике саны шушы чагыштыруда семантик бәйләгеч вазифасын үти. Соңгы мисал аналогия буенча бара.

Алдагы семантик төркемнең исеме- "Көрәш". Әлеге семантик төркемгә алдагы мисаллар керде:

***Ике*** *козгын талашса,бер козгынга җим җитәр [И.Н. Тат.хал.мәк.т.1: 606]*

***Ике*** *карчыга талашканда,бер мендәрлек йон чыга [И.Н. Тат.хал.мәк.т.1: 606]*

***Ике*** *шоңкар талашса, бер каргага җим булыр [И.Н. Тат.хал.мәк.т.1: 607]*

Китерелгән барлык мисалларда да *ике* саны- микъдар саны лексик- грамматик төркемчәсенә карый һәм объектның данә исәбен белдерә. Шунысы кызыклы, барлык мисалларда да *ике* санының саналмышлары исем сүз төркеменең тематик яктан кошлар төркеменә кергән сүзләр- кош атамалары. Алар арасында: *карчыга, шоңкар, козгын, карга*. Шул рәвешле, *ике* саны кошларның талашу нәтиҗәсен чыгарыга ярдәм итә. Мәкальләрдә талашу темасы чагылыш тапса да, мисалларда ирония пафосы өстенлек итә, чөнки

кошларның талашуыннан соң *җим, йон* кала. Димәк, *ике* саны ярдәмче сүзләр белән бергә “Көрәш” семантик төркемен барлыкка китерә.

Чираттагы семантик төркем исә, “Икеяклылык” дип атала.

*Комган* ***ике*** *авызлы [И.Н. Тат.хал.мәк.т.2: 555]*
***Ике*** *йөзле дус- ике яклы пычак[И.Н. Тат.хал.мәк.т.3:32]*
*Таяк* ***ике*** *башлы була, юашы сезгә[И.Н. Тат.хал.мәк.т.3:357]*

Әлеге төркемгә кергән *ике* саны барлык мисалларда да- микъдар саны. Мисалларда *ике* саны сыйфат сүз төркемен, исем сүз төркемнәрен ачыклап килгән. *Ике* саны сурәтләнә торган предметның данә исәбен генә белдерми, шуның белән бергә ул предметны ике яктан ачыклап күрсәтә, ике яклы булуына басым ясый диярргә була. Мисал өчен, комганның ике авызы бар, дус ике яклы пычак белән чагыштырыла, таякның ике башы барлыгы күзгә алына. Мәкальләрдә *ике* саны ярдәмендә раслау пафосы тудырыла. Мисаллар уңай коннотациягә ия.

Алдагы семантик төркем “Җүләрлек” дип аталды.

*Җүләр* ***ике*** *түләр [И.Н. Тат.хал.мәк.т.3:599]*
***Ике*** *чабата бер кием,* ***ике*** *җүләр бер тиен[И.Н. Тат.хал.мәк.т.3:602]*
***Ике*** *җүләргә бер акыл да җитә[И.Н. Тат.хал.мәк.т.3:602]*

Күренгәнчә, *ике* саны кабат предметларның данә исәбен белдерә. *Ике* санының саналмышлары- фигыль сүз төркеме, нумератив сүзләр (*тиен*), исем сүз төркеме. *Ике* саны фигыль сүз төркемен ачыклап килгәндә, җүләрнең холкын, эчке сыйфатларын ачыклый. Икенче мисалда, *ике* саны *чабата* һәм *җүләрне* үзара чагыштырып, җүләрлек семантикасын тудыра. Ике компоненттан оешкан әлеге мәкальдә *ике* саны бәйләүче чара булып та тора.

Тагын бер семантик төркемгә “Эшнең өзлеклелеге”, яки “Эшнең бер- бер артлы баруы” дигән исем бирелде : ***Ике*** *ишет, бер сөйлә [И.Н. Тат.хал.мәк.т.3:491]*

Китерелгән мисалда, *ике* һәм *бер* саннарының саналмышлары фигыль булып тора. *Ике* саны эш процессын ачыклый. Фикерләү фигыльләре (*ишет, сөйлә*) турыдан туры саннарга бәйле. Шул рәвешле, *ике* саны эшнең бер- бер артлы барырга тиешлелеген мәкальдә раслау пафосы аша күрсәтә.

Соңгы семантик төркем “Даимилек, үзгәрмәүчәнлек” исемен алды. Мисал итеп, алдагы мәкальне китерергә мөмкин: ***Ике*** *дөнья бер килмәс [И.Н. Тат.хал.мәк.т.3:987]*

*Ике* саны тормыш тематик төркеменә кергән исем сүз төркемен ачыклап килә. *Дөнья- ике* санының саналмышы. Бу мисалда *ике* саны тормышның үзгәрмәүчәнлеген һәм даимилеген күрсәтә. Бу семантик төркемне тудырырга *ике* санына *бер* саны ярдәм итә.

Шулай итеп, *ике* санын семантик яктан тикшерү дәверендә алдагы семантик төркемнәр аерылып чыгарылды: “Ялкаулык”, “Капма-каршылык”, “Бердәмлек”, “Көрәш”, “Икеяклылык”, “Җүләрлек”, “Эшнең өзлеклелеге”, “Даимилек, үзгәрмәүчәнлек”. Шул рәвешле, *ике* саны сигез семантик төркемгә бүленде. *Ике* санын семантик төркемнәргә бүлергә ярдәмче сүзләр булышты: хәрәкәт, фикерләү фигыльләре, тормыш (*дөнья*) һәм кошлар ( *карчыга, шоңкар, козгын, карга*) тематик төркемнәренә кергән исем сүз төркемнәре, нумератив сүзләр (*тиен*). Еш кына *ике* санының семантик төсмерен ачыкларга паралингвистик чаралар (көттерү паузасы) һәм мәкальнең төзелеше, структурасы ярдәм итте.

*Файдаланылган әдәбият исемлеге:*


1. Исәнбәт Н. Татар халык мәкальләре 3 томда: Том 1.- Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1959.- 915 б.
2. Исәнбәт Н. Татар халык мәкальләре 3 томда: Том 2.- Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1963.- 960 б.
3. Исәнбәт Н. Татар халык мәкальләре 3 томда: Том 3.- Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1967.- 1014 б.
4. Татар грамматикасы. –Т.II.- М.: “ИНСАН”, Казань: “ФИКЕР”, 2002.- 448 с.

5. Татар лексикологиясе: өч томда / проект җит. М.З. Зәкиев; ред. Г.Р.Галиуллина. – Казан: ТӘһСИ, 2015. – Т. I. – 352 б.
6. Хисамова Ф.М. Татар теле морфологиясе: югары уку йортлары өчен дәреслек. Казан: Мәгариф, 2006.- 335 б.
7. Инновационные процессы в науке и образовании: монография. Под общ. Ред. Г.Ю. Гуляева - Пенза: МЦНС «Наука и просвещение».- 2017- 204 с.

# МАТЕМАТИК ИСӘПЛӘҮЛӘРДӘ ЭКОЛОГИЯ

*Ахметова Адилә, 10 нчы сыйныф укучысы,*
*Фәнни җитәкче: Бикмухаметова Гөлниса Рифат кызы*
*ТР Кукмара муниципаль районы “Нырты урта мәктәбе”*

Нигә сандугачлар сирәк сайрый,
Авылым урап алган тирәклләрдә?
Балыклар соң нигә үлеп бара
Бормаланып аккан елгаларда?
Туфрагың да агуланып беткән,
Шиңә бара нигә чәчәкләр?
Нигә чара юксың бу хәлләргә,
Кайгырмыйсыз нигә, кешеләр?        (А.Метшина)

Һәм мин уйланып калдым . Чыннан да ни өчен шулай, моннан чыгу юллары бармы? Шушы һәм башка сорауларга җавап табу өчен мин үземнең фәнни-эзләнү эшемне башлап җибәрдем.

Хәзерге көндә экологик проблемаларның берсе: көнкүреш чүп-чары белән биосфераның пычрануы. Төрле мәгълүматлар буенча планетаның һәр кешесенә уртача бер елга 300 килограмнан бер тоннага кадәр чүп-чар туры килә. Әгәр дә җыелган чүп-чар бетерелмичә, эшкәртелмичә бер өемгә җыелып барса, 10 елдан соң кешелек чүп астында калачак. Көнкүреш чүп-чарының зур өлеше табигый шартларда бик озак вакыт таркала, ә кайберәүләре бөтенләй таркалмый. Мондый чүп-чар елдан-ел арта бара. Бу сәнәгать, авыл хуҗалыгы, шәһәрләр белән беррәттән аерым алынган халыкка да хас күренеш. Бу безнең авылыбызга да кагыла. Йорт тирәләренең, юл кырыйларының чуп-чар белән тулып ятканын мин гел күреп торам. Якын тирәдәге урманнарны полиэтилен өемнәре, корсерва банкалары ямсезләп бетерде. Чуп-чарның кая китүе мине бик кызыксындырды. Мин безнең авылыбызны бик яратам, әмма миңа урамнарыбызның пычрануын күрүе бик авыр, шуңа күрә мин бу проблема буенча тикшеренү үткәрергә булдым.

Тикшеренүнең иң мөһим соравы: авылыбыз территорясының көнкүреш калдыклары белән никадәр пычрануы, аларның кешеләргә һәм хайваннарга ничек тәэсир итүе һәм халыкнын бу проблемага ничек каравы.

Гаиләдә көн саен нәрсәдә булса чыгарып ташлыйлар. Чүп-чар полигоннарга илтелә. Кайбер кешеләр чүпләрен якындагы агач төбенә дә, берәр өй почмагына да атарга мөмкин. Бу чүп-чар еллар буы ачык һавада искереп ята, атмосфераны, җир асты суларын пычрата, тирә-юннең тышкы кыяфәтен боза. Сәнәгать, транспорт, төзелеш предприятиеләреннән, кибетләрдән бик күп чүп-чар чыгарыла. Юл кырыйларында, урманнарда пакетлар белән чүп-чар гына түгел, ә ватык өй җиһазлары, күгәргән машиналар да күрергә мөмкин.

Чүп-чар экренләп цивилизациянең иң куркыныч дошманына әверелә.

Көнкүреш чүп-чары     спецотходлар     сәнәгать чүп-чары

Һәр гаиләдә чүп чиләге көн саен чүп контейнерына сәяхәт кыла.

Көнкүреш калдыклары:

- кәгазь, китап, дәфтәр, гәҗит;
- пыяла банкалар һәм шешәләр;
- консерва банкалары;
- яшелчә кабыклары, йомырка кабыклары (органик калдыклар);
- пластик савытлар;
- катыргыдан ясалган сөт һәм сок калдыклары;

- полиэтилен пакетлар һәм капчыклар;
- искергән тукыма (ямауга яраксыз оекбашлар, колготкилар һ.б.)
- агачтан ясалган эшләнмәләр;
- тимердән, калайдан, резинадан әйберләр (мәсәлән, иске уенчыклар) һәм башка әйберләр.

Һәркайсыбыз даими күп кенә әйберләр белән файдалана, аларның барсының да куркынычсыз булмавы турында уйлап та тормыйбыз. Күбесенчә бу әйберләрне сак кулланырга, ә файдаланганнан соң ташламаска һәм уенчыкка әйләндермәскә кирәк.

Спецотходлар:
- батарейкалар;
- бояу, лак, клей калдыклары;
- бизәнгеч калдыклары (иннек, лак, лак бетерә торган сыекча);
- кулланылмаган, яисә яраклылык вакыты чыккан дарулар;
- көнкүреш химиясе (шампунь, порошоклар һ.б.)
- терекөмешле термометрлар.

Эшчәнлек вакыты чыккан электротехника һәм электроника бик куркыныч (аларның төзелешендә терекөмеш, бакыр, кургаш һ.б. кулланыла).

Спецотходларны башка чуп-чар белән ташларга ярамый, чөнки алар әйләнә-тирә мохиткә һәм кеше сәламәтлегенә зур зыян китерәләр.

Көнкүреш һәм спецотходлардан тыш, сәнәгать предприятиеләре калдыклары да бар:
- радиоактив калдыклар;
- терекөмеш һәм аның кушылмалары – химия сәнәгате калдыклары;
- мышьяк һәм аның кушылмалары – металл җитештерү һәм җылылык электростанциясының калдыклары;
- кургаш кушылмалары һ.б.

Тикшеренүләр нәтиҗәдәсендә билгеләнгәнчә,безнең чүп-чар составына гыйбарәт катлаулы төрле химик катнашмалар керә.

Һәр гаиләдә, һәр кеше чүп-чар ташлый һәм елдан-ел чуп-чар арта бара.

Соңгы елларда чүп артуның берничә сәбәрләрен атап үтәргә мөмкин:
- бер тапкыр кулану товарларының җитештерү үсеше;
- ялтырап торган, синтетик капларның саны артуы;
- тормыш дәрәҗәсенең күтәрелүе, ул кулланылуга яраклы әйберләрне яңага алыштырырга мөмкинлек бирә.

Чүп-чар тышкы кыяфәтне генә бозып калмый. Ул әйләнә-тирә мохиткә зур зыян китерә. Без бу чуп-чарның безгә пычранган җир асты сулары, агулы тузан рәвешендә кире кайтуы турында уйламыйбыз. Чишмә, кое сулары эчәргә яраксыз, яшелчә һәм җиләк-җимеш агуланган булачак.

Күпчелек кешеләр бу проблеманы бөтенләй күрми. Шуңа күрә, чүп-чарны рөхсәт ителмәгән урыннарга ташлый. Чүплек (кечкенә генә булуына да карамастан) кешеләргә зур зыян сала.

Җил тузанны туздыра, этләр аны тарата. Калдыклар таркалу вакытында барлыкка килгән матдәләр атмосфера һавасын боза, шул ук вакытта, яңгыр суы агулы матдәләрне юдырып чыгара. Бүгенге көндә туфракның һәм сулыкларның көнкүреш калдыклар белән пычрануы глобаль проблемаларның иң зурысы булып тора.

Чүплекләр тычканнар, күселәр, күпчелек бөҗәкләр үрчеве өчен иң уңайлы урын.

Теоретик материалны өйрәнгәннән соң, тикшеренүләр үткәргәннән соң мин мондый фикергә килдем: чүп-чар проблемасын хәл итүне хәзер үк башларга, һәм иң беренче чиратта, үзеңнән, үзеңнең фатирдан, өеңнән, мәктәптән, ишегалдыннан башларга кирәк.

Үзем өчен мин "Син нәрсә эшли аласың?" дигән белешмәлек төзедем.

Әгәр дә һәр кеше бу кагыйдәләрне үтәсә, безнең әйләнә тирә әз генә булса да чистарачак:

- Даими рәвештә мәктәп, йорт территорияләрен җыештырырга.
- Чүп-чарны теләсә кая ташламаска.

- Урманда, сулык яннарында, ял итү урынында чүп-чар калдырмаска.
- Макулатура җыярга һәм тапшырыга (бу табигый ресурсларны саклап калырга булыша).
- Дәфтәрләрне, кәгазне саклап кулланырга.
- Дәреслекләрне, китапларны саклык белән тотарга.
- Үзең кулланмаган әйберләрне аз керемле кешеләргә бирергә.
- Ашарга пешергәндә азык-төлекне яраксыз калдыкларга әйләндермәскә.
- Иске әйберләргә "икенче тормыш" бүләк итәргә.

## ТӘМӘКЕ – ӘКРЕН ТӘЭСИР ИТҮЧЕ МИНА

*Габбасова Лиана, 7 нче сыйныф укучысы,*
*фәнни җитәкче: Габбасов Айнур Габделнур улы*
*ТР Әгерҗе муниципаль районы "Ләбиб Айтуганов исемендәге*
*Девятерня төп гомум белем бирү мәктәбе"*

Безнең үз гомеребездә тәмәке хакында әти-әниләребездән, укытучылардан бик күп ишеткәнебез бар инде. Ләкин тәмәкенең зыяны турында аңлатуларга карамастан, ул кешеләр арасында тартучылар да очрый. Бертөрле сөйләп, икенче төрле эшләргә ярамый бит инде. Әйе, ярамый! Без сәламәт яшәү рәвеше алып барырга, башкаларга да, киләчәк буыннарга да уңай гадәтләребез, яхшы гамәлләребез белән үрнәк булырга тиешбез.

Тәмәкенең зыяны турында газета-журналларда күп язалар, телевизор һәм радиодан сөйләп торалар, интернетта да бик күп мәгълүмат табарга була. Ләкин, тәмәкенең зыяны турында белүгә карамастан, әйләнә-тирәбездә тәмәке көйрәтүчеләр бихисап күп. Араларында яшь-яшь кызларның, әни кешеләрнең булуы зур курку, борчу тудыра. Алга таба сәламәт буын калырмы? Кешелек дөньясын ни көтә?

Тарих ни сөйли? Тәмәкене бик борынгы заманнарда ук тарткан булсалар кирәк. Безнең эрага кадәр 5 нче йөздә яшәгән грек тарихчысы Геродот Русьның көньягында яшәүче скифларның һәм Африка халыкларының ниндидер үләнне яндырып, төтен иснәүләре турында мәгьлүматлар калдырган. Һиндларның, кытайларның, японнарның һәм кореялеләрнең дә тәмәкене безнең эрага кадәр ук кулланулары билгеле. Тәмәке турында аныграк мәгьлүматлар Христофор Колумбның Американы ачу вакытына туры килә (1492 нче еллар). Христофор Колумб белән Америкага барган матрослар тәмәке тартырга өйрәнгәннәр һәм бу гадәтне Европага алып кайтканнар.

Россиягә тәмәке 17 нче йөз башында инглиз сәүдәгәрләре тарафыннан кертелә һәм бик тиз тарала. Ләкин тикшеренүләр Русьта тәмәкенең Америка материгы ачылганчы ук билгеле булуын күрсәтәләр. Ә Петр 1 Голландиядән тәмәке тартырга өйрәнеп кайта һәм тәмәке тартуны тыймый башлый, ачыктан-ачык сатырга рөхсәт итә. Соңга таба Кырымда һәм Кавказда тәмәкене махсус плантацияләрдә игәргә керешәләр. 1850 елларда инде 30 дан артык губернада тәмәке игелә. 1913 елда Россиядә 25,9 миллиард данә папирос, 87,9 мең тонна махорка эшләп чыгарылган.

Европада тәмәкене башта авыруларны дәвалау өчен дә файдаланганнар. Яшелчә һәм җимеш агачы корткычларына, борча, кандала, көя кебек бөҗәкләргә каршы көрәшү өчен дә тәмәке файдаланылган. Соңга таба тәмәке тартмаучыларга караганда тартучыларның күбрәк авыруларын күреп, ягъни тәмәкенең кеше өчен зарарын аңлап, Европадагы кайбер илләрдә аңа каршы көрәш алып бара башлыйлар.

Башка илләрдәге кебек, Россиядә дә тәмәкегә каршы көрәш башланып китә. Борынгы йортларның күпчелеге агачтан салынган була. Хөкүмәт, янгын чыгудан куркып, тәмәке тартучыларга каршы төрле җәзалар кулланган. Кесәсендә тәмәке табылган кешене, кайдан алганын әйткәнчегә кадәр, чыбыркы белән кыйнаганнар, ә тәмәке сатучының борынын

кисеп, сөргенгә сөргәннәр. Россиягә чит илләрдән тәмәке кертү тыелган. Ләкин бу чара көтелгән нәтиҗәне бирмәгән. Хәзерге вакытта тәмәке барлык илләрдә дә папирос, сигара, сигарет, махорка формасында кулланыла. Ә тәмәке эшләп чыгаруда АКШ беренче урында тора. Анда тәмәкене мактыйлар, аны файдалы итеп күрсәтергә тырышалар.

Бүгенгесе көндә жир шарында тәмәке тартучылар саны артканнан-арта бара. Аларның һәрберсе көненә 30 сумлык тартса да, көн саен 30 миллиард сум чын мәгънәсендә жилгә очып бара.

Тәмәке тартуның никадәр киң таралганын, "зәңгәр елан" бөҗраларының ничек итеп торган саен күбрәк сандагы корбаннарны эләктереп алуын күреп, ирексездән сорау бирәсең: кешеләр ни өчен тәмәке тарта башлыйлар соң?

Тәмәке тартуның сәбәпләрен өйрәнгән авторларның барысы да тәмәке тарту теләген тудырган төп сәбәп - кызыксыну дигән нәтиҗәгә киләләр. Шунысы характерлы, күп кенә кешеләр әле үсмер чакта һәм хәтта бала чакта ук тәмәке тарта башлыйлар.

Балаларның башкаларга ияреpгә яратуларын беләбез. Тәмәке тартучы ата-аналарын, өлкән иптәшләрен, һәм башка әйләнә-тирәдәгеләрне күргән баланың башкалар эшләгәнне кабатлыйсы килүе табигый. Бу эштә гаиләнең тискәре роль уйнавы бик ачык. 15-17 яшьләрдәге укучылардан сораштыру нәтижәсендә, ата-анасы тәмәке тартмаган гаиләләрдә балаларның дүрттән бер өлешенең, ә ата-аналары тәмәке тарткан гаиләләрдә яртысының тәмәке тартуы билгеле булды. Тәмәке тартуның таралуында мода да гаепле.

Тәмәке тарту гадәтенең ныгуына китергән сәбәпләрнең берсе - тәмәкене эшкә сәләтлелекне арттыра дип исәпләүдә. Еш кына мондый сүзләрне ишетергә мөмкин: "Тәмәкенең зарарлы булуын мин яхшы беләм, ә менә шуннан башка эшли алмыйм. Кайчакта арыйсың, бер нәрсә дә аңламый башлыйсың, ә бер-ике тапкыр папирос суырдыңмы, зиһенең ачылып китә". Беренче карауга, тәмәкенең тәэсире турындагы мондый фикер шактый нигезле булып күренергә мөмкин. Тәмәке тартучыны игътибар беләнрәк һәм озаграк күзәтеп карыйк әле. Аз гына вакыт үтү белән ул яңадан папироска сузыла. Эш нәрсәдә соң? Ни өчен "тәмәке эликсиры" шулай аз вакытка гына тәэсир итә?

Тәмәке төтене тәэсирендә баш миендәге кан тамырлары бераз киңәя, тәмәкече моны үзенә көч керү дип кабул итә. Әмма, тәмәкенең мондый тәэсире бик азга гына җитә. Берничә минуттан соң инде баш миендәге киңәйгән кан тамырлары яңадан кысыла, шуның өстенә бу кысылу элеккегә караганда ныграк сизелә торган була. Нәтиҗәдә, баш миенең кан белән тәэмин ителүе сизелерлек дәрәҗәдә начарлана һәм эшкә сәләтлелек кими. Көчәя төшкән аруны "куып җибәрергә" тырышып, тәмәкече икенче папиросны, аның артыннан өченчесен, дүртенчесен ала, үз энергиясенең барлык резервларын тәмам бетергәнчегә кадәр тарта. Тәмәке тартучылар папирос аруны киметә, димәк, тәмәке тартуны ару-талу белән көрәш чарасы итеп санарга мөмкин дип раслыйлар. Ләкин бу фикер дә дөрес түгел. Папирос тартканнан соң була торган һәм югарыда әйтеп үтелгәнчә, баш миенә кан килүгә бәйле кыска вакытлы көч арту, энергиянең шуннан соң төшүе белән тулысынча юкка чыгарыла.

Тәмәке белән азыкны алыштыруның һич тә мөмкин түгеллеге һәркемгә дә аңлашылса да, папирос тартып ашыйсы килүне чыннан да киметү, ә кайвакыт хәтта тулысынча басу ни өчен мөмкин булганлыгын бер кеше дә аңлатып бирә алмый. Бу хәл тәмәке төтенендәге агулы матдәләрнең канга сеңеп, ашказаны һәм эчәклек стеналарында урнашкан нерв очларына тәэсир итүләре һәм ашыйсы килү турында сигнал бирүче нерв импульсларының тапшырылуын тоткарлаулары белән аңлатыла. Тәмәке тартудан организмга килә торган зарар исә ап- ачык.

Тәмәкенең сулыш органнарына зыяны әйтеп бетергесез зур. Сулыш органнары - тәмәке төтенендәге зарарлы матдәләрнең организмга керү юлы ул. Тәмәке агуларының беренче удары нәкъ менә сулыш органнарына төшә. Тәмәке төтененең каты продуктлары да (корым), газ хәлендәгеләре дә бугазның трахея, бронхлар, бик кечкенә бронхиолалар һәм үпкә куыкчыклары – альвеолаларның лайлалы ярысын ярсыта. Нәтиҗәдә сулыш юлларының хроник ялкынсынуы башлана. Тәмәке

тартучылар еш кына бронхиттан интегәләр. Аларны иртәләрен аеруча көчәя торган ютәл газаплый. Ютәл пычрак сары төстәге какырыкның күп бүленеп чыгуы белән бергә бара, тавыш җепселләренең системалы ярсытылуы тәмәке тартучыларның тавышын тупас, хырылдаучан итә. Моның күп кенә очракларда профессиональ вазифаларны үтәүгә (җырчы, педагоглар очен) киртә булуы ихтимал. Бер ел буе тәмәке тартучының үпкәсе аша 800 г чамасы тәмәке дегете уза. Паталогоанатомик тикшерү вакытында озак вакыт буе тәмәке тарткан кешенен үпкәсе тәмәке тартмаган кешенекенә караганда карарак төстә булып чыгуы очраклы түгел. Даими рәвештә ютәлләү үпкә тукымасының сыгылмалылыгын киметә, альвеолаларның сузылуына китерә.

Тәмәке тартучыларда үпкәнең төрле йогышлы авыруларга каршы торучанлыгы шактый түбән. Тәмәке тарту үпкә туберкулезы белән дә бәйләнгән.

Соңгы ун еллар дәвамында һәр җирдә үпкә рагыннан үлүчеләр санының арта баруы теркәлеп килә. Барлык илләрнең дә галимнәре үпкә рагы белән авыручыларның артуында тәмәке тарту зур роль уйный дигән нәтиҗәгә килделәр. Хәзерге заман статистика мәгълүматларына караганда, тәмәке тартучыларда үпкә рагы белән авыру ихтималы тәмәке тартмаучылардагыга караганда чама белән 10 тапкырга күбрәк. Тәмәкене иртә тарта башлаучыларда һәм шулай ук тартылып бетмәгән сигаретларны яңадан кабызып, тагын да тирәнрәк суырырга гадәтләнгән кешеләрдә авыру ихтималының аеруча арта төшүе беленде.

Китерелгән мәгълүматлардан мондый нәтиҗә ясарга мөмкин: әгәр тәмәке тарту туктатылса, үпкә рагы кебек каты һәм тормыш өчен куркыныч чир белән авыручылар саны шактый кимер иде.

Тәмәке тарту йөрәк-кан юллары системасын да зарарлый. Тәмәкенең йөрәк-кан юллары системасына тәэсире катлаулы һәм күп төрле. Барыннан да элек йөрәк тибешенең ешаюы үзенә игътибарны җәлеп итә. Билгеле булганча, сәламәт кешенең йөрәге минутына уртача 70 тапкыр кыскара, ә тәмәке тарту йөрәк тибешенең ешлыгын 80-90 тапкырга җиткерә.

Тәмәке тартуның бөер өсте бизләренең артериаль басымны 20-25% күтәрү торган гормональ матдәләр бүлеп чыгаруына булышуы тәҗрибә юлы белән исбат ителгән. Бу исә йөрәккә өстәмә эш дигән сүз, чөнки кысылган кан тамырлары аша канны үткәрү өчен йөрәк күбрәк энергия сарыф итәргә мәҗбүр була. Кан тамырларының диаметры кечерәю нәтиҗәсендә органнарны кан белән тәэмин итү начарлана, тән температурасы түбәнәя. Углерод окисе сулау нәтиҗәсендә тәмәке тартучыларның канында карбоксигемоглобин арта, ә бу йөрәк мускулларын кислород белән тәэмин итүне начарлата.

Системалы рәвештә тәмәке тартуның атеросклерозга китерүе ихтимал, ә атеросклерозның таралуы йөрәкнең ишемия белән авыру очракларын ешайта, аны хәзер еш кына "безнең гасыр авыруы" дип атыйлар. Ишемия авыруы дигәннән, йөрәкне тукландыручы кан тамырларына кан килүнең кинәт кимүе белән бәйле булган барлык йөрәк авыруларын һәм аның эшчәнлеге бозылуларны аңларга кирәк.

Ишемия авыруына китерүче сәбәпләр төрле-төрле, әмма мондый хәлне күбесенчә атеросклероз һәм гипертония китереп чыгара.

Үз чиратында гипертониянең һәм аеруча атеросклерозның килеп чыгуына шактый дәрәҗәдә тәмәке тарту гаепле.

Балтыр һәм буын артерияләренең зарарлануы нигезендә килеп чыккан вакыт-вакыт аксау кебек кан юллары авыруы да тәмәке тарту белән бәйләнгән. Кешеләр башта аяк балтырларында һәм тездә авырту сизүдән зарланалар: тире чымырдый, суына һәм сызлый. Авырунын соңгы стадияләрендә вакыты белән шулкадәр көчле авыртулар башлана ки, кеше атлап йөрү сәләтен югалта. Кайчакларда бу авыруның бармаклар гангренасына китерүе ихтимал. Барлык бу авыру күренешләре аяк һәм кулларның кан белән тәэмин ителеше бозылуга бәйләнгән. Вакыт-вакыт аксау тәмәке тартучыларда тәмәке тартмаучыларга караганда шактый ешрак очрый.

Тәмәке тарту нерв системасы өчен дә зыянлы. Барлык органнар һәм системалар арасында тәмәкегә иң сизгере- нерв системасы. Нерв системасы аша организмның аны чолгап алган тирәлек белән элемтәсе тормышка ашырыла. Нерв системасы тәмәке агуларының тәэсиренә бик тиз җавап бирә.

Тәмәкене озак һәм күп тартучыларда невротик хәл өчен характерлы билгеләр: тиз ару, ярсыну, хәтернең начарлануы, нервлылык, баш авырту башланырга мөмкин. Тәмәке тарту- сизү органнары функциясенә начар тәэсир итә. Күп кенә тәмәке тартучыларның, мәсәлән, татлы әйбер яратмавы билгеле, чөнки никотин, тәм сизү органнарының очын зарарлап, тәм тоюны начарлата. Тәмәкене бик күп тартучылар начар күрә башлаудан зарланалар, кайчакта алар төс аермый башлыйлар. Болар барысы да тәмәке агуларының күрү нервларына токсик тәэсире белән аңлатыла. Тәмәке тарту ишетүне дә начарлата. Тәмәке тартучының "колагы томалана", чөнки тамак-борын гына түгел, ишетү аппаратының да кайбер урыннары даими рәвештә ярсытылып тора, шул ук вакытта ишетү нервлары да ярсына һәм ишетү начарлана. Тәмәке белән хроник рәвештә агулануның периферик нерв системасы авырулары белән бергә бару очраклары турында күп язылган. Тәмәке тарту төрле нерв системасы авыруларын көчәйтергә, кайвакыт кешене бик нык гарип итеп калдырыга мөмкин.

Тәмәке тарту ашкайнату органнарын да сафтан чыгара. Тәмәке төтене, авыз куышлыгына кереп, телне, уртларны, каты һәм йомшак аңкауны, тамакны ярсыта. Тәмәке төтене тәэсире астында тешнең эмале чатный. Тешләр авыз куышлыгында һәм йоткылык өстендә булган череткеч микроблар белән зарарлана һәм бозыла башлый.

Тәмәке тартучының авызыннан еш кына начар ис килә. Тәмәке төтене селәгәй бизләрен ярсыта, нәтиҗәдә тәмәке тартканда бик күп селәгәй бүленеп чыга. Тәмәке тартуның ирен һәм тел рагы үсүгә китерүче сәбәпләрдән берсе булуы да билгеле. Бөтендөнья сәламәтлек саклау оешмасы мәгълүматларына караганда, авыз куышлыгы органнары һәм үңәч рагыннан үлүчеләр саны тәмәке тартучылар арасында тәмәке тартмаучылар группасындагыга караганда, 4 тапкырга артыграк.

Никотин ашказаны һәм эчәкләрнең кыскаруын тоткарлый. Никотин тәэсире астында еш кына эчәкләрнең тышка чыгару өлешендә ирексез спазмалар була. Тәмәке тарту геморроидаль кан агуларга сәбәп була.Тәмәке тарту бавырга зарарлы тәэсир итә. Тәмәке тартучыларда еш кына бавырның зураюы күзәтелә тәмәке тартуны туктатканда ул бетә. Хроник рәвештә тәмәке тартуның күп кенә очракларда ашказаны асты бизе авыруларына китерүе билгеле. Тәмәке тартучыларда гына түгел,ә бәлки даими рәвештә тәмәке тартылган бүлмәдә утырырга мәҗбүр булган кешеләрдә дә хроник ашказаны-эчәк авыруларының көчәюе беленде.

Ә тәмәке тарту кыз бала организмына ничек тәэсир итә соң? Тәмәке тарту олы кеше организмы өчен куркыныч икән, ә бала организмы өчен бу куркыныч берничә тапкырга арта. Йөкле хатын тәмәке тартса, туачак балага төзәтеп булмаслык зарар китерелә. Төрле илләрдә үткәрелгән тикшеренүләр йөкле вакытта тәмәке тарткан хатыннар тудырган балаларның авырлыгы тәмәке тартмаучы аналарның балалары авырлыгына караганда уртача 150-240г га кимрәк булуын курсәтте.

Тәмәке тартылган бүлмәдә кечкенә бала начар йоклый, начар ашый. Еш кына аның эче бозыла. Бала физик һәм акыл үсеше ягыннан үз яшьтәшләреннән калыша. Тәмәке тарта башлаган үсмерләр тиз ярсучан, аз канлы булалар, мәктәптә начар укыйлар, спортта арттa калалар, еш авырыйлар. Балалар гадәттә качып, ашык-пошык тарталар. Ә бит тәмәке тиз янганда төтенгә никотин акрын янгандагыдан 2 тапкырга күбрәк күчә. Димәк, тәмәке тартуның зарары тагын да арта төшә. Үсмерләр, кагыйдә буларак, папиросны төбенә кадәр тартып бетерәләр, еш кына төпчек тарталар, ягъни тәмәкенең нәкъ менә агулы матдәләр аеруча күп булган өлешеннән файдаланалар. Папирос сатып алганда балалар өлешчә үзләренә иртәнге ашка бирелгән акчаларын тоталар. Еш кына балаларның бөтен компания белән бергәләп, авыздан-авызга биреп, бер үк папиросны тартуларын күрергә мөмкин, бу хәл

йогышлы авырулар таралуга булышлык итә. Җирдән яки идәннән табып алынган төпчекләрне тарту тагын да куркынычрак.

Тәмәке тарту һәм гомер озынлыгы бер-берсенә бик нык бәйле. Игътибар белән карасаң, күп еллар буе туктаусыз тәмәке тарткан кешенең яшьтәшләреннән шактый олы күренүен чамалап була.

Тәмәке тарту зарарлы! Бу турыда бөтен кешедә белә һәм хәтта тәмәке тартучы үзе дә моны инкарь итми. Шулай да җир шарындагы барлык ирләрнең яртысы һәм хатын-кызларның якынча 30% тәмәке тарта.

Тагын шуны өстәргә кирәк: үзе тәмәке тартмыйча, тәмәке төтенен сулаган кешеләргә дә төтеннең зарары бик зур. Тәмәке төтене булган бүлмәдә бер сәгать торган кеше үзе 4 сигарет тарткан кеше кадәр агу сулый, чөнки бөтен төтеннең 68% һавага чыгып бара.

Тикшеренү-эзләнү эше барышында, тәмәкенең килеп чыгуы, безнең илебезгә эләгү тарихы, тәмәке тартуның сәбәпләре, кан әйләнеше, сулыш һәм ашкайнату, нерв системасына тәэсире өйрәнелде. Шулай ук тәмәке тартучыларның әйләнә-тирәдәгеләрне дә агулавы, тәмәке тартуның кыз бала организмына тәэсире турында материаллар туплап анализланды. Тикшерү эшенең бер ысулы төрле әдәбияттан тәмәке турында материаллар туплап анализлау иде. Икенче ысул: авылыбызда яшәүче тәмәке тартучы һәм тартмаучы ир-егетләр арасында анкета уздыру булды. Анкета уздыруның максаты авылыбыздагы тәмәке тартучы һәм тартмаучы кешеләрнең сәламәтлеген чагыштыру, тарту сәбәпләрен ачыклау һәм аз булса да кешеләрдә тәмәкегә карата начар тәэсир тудыру иде

Кешенең сәламәтлеген какшатучы күп кенә зарарлы гадәтләр арасында тәмәке тарту төп урыннарның берсен алып тора. Сер түгел, яшүсмерләр мәктәп елларында тартырга өйрәнә. Һәр бала зарарлы гадәтләрнең кеше организмына нинди зыян китерүе турында белергә тиеш. Зарарлы гадәтләрнең яшь буынга, жәмгыятебезгә гаять зур зыян китерүе хакында аңлатуны күздә тотып, мин “Тәмәке әкрен тәэсир итүче мина” дигән темага анкета уздырдым. Анкетада 88 кеше катнашты, шуларның 63е тартучылар, ә 25е тартмаучылар. Катнашучыларның яше 15 яшьтән-70 яшькәчә кадәр иде.

Тикшерү эшләре аша мин түбәндәгеләрне ачыкладым:

-тәмәке тарта башлауның сәбәпләре арасында беренче урында кызыксынучанлык (47,5%) тора, тарта башлау вакыты аларның үсмер чагына, кайберләренең исә бала чагына туры килә. 18,4% кеше башкалардан калышмаска тырышып, 13,8% кеше башкаларның сүзен тыңлап һәм эшсезлектән тарта (таблица 1).

Сораштыру үткәргән 88 кешенең 63 е- тәмәке тартучы кешеләр. Алар арасындагы авырулар ешлыгын анализлаудан күренгәнчә, тәмәке белән дуслык 12-20 яшь арасында башлана. 12-15 яшьтән тарта башлаучылар арасында 20-30 яшьтә сулыш органнары авырулары 33,3%, йөрәк-кан тамыры авырулары 26% ка җитүе күзәтелә. Тәмәке тартучыларның яше арткан саен, аларда авырулар ешлыгы да арта. Алар арасында сулыш органнары 48,05%, кан әйләнеше системасы авырулары 40,1%, ашкайнату органнары авырулары 38,3%, нерв системасы авырулары 31,2%, организмда көчсезлек 26,5% булуы күзәтелә (таблица 2) .

Сулыш органнары авырулары арасында киң таралганнары ютәл, бронхит авырулары тора. Шулай ук тәмәке тартучылар салкын тию, грипп авырулары белән тәмәке тартмаучыларга караганда ешрак авырыйлар. Кан әйләнеше системасы авырулары арасында киң таралганнары кан басымы югары булу күзәтелә, шулай ук инсульт, инфаркт авырулары 40-70 яшьлек тәмәке тартучылар араында еш була.

Ашкайнату органнары авырулары арасында гастрит, язва тамыр җәйгән. Шулай ук ашказанында рак, эчәклектә төрле авырулар булу очраклары бар.

Сораштыру үткәргән 28 кеше арасыннан 25 кеше тартмаучылар иде. Алар арасында 40 яшькә кадәр авыручылар саны бөтенләй юк. 40 яшьтән соң тармаучылар арасында да авыручылар күренә башлый, ләкин тартучылар белән чагыштырганда аерма күпкә зуррак. Тартмаучылар арасында авырулар ешлыгы түбәндәгечә: сулыш органнары авырулары 13,3%,

кан әйләнеше системасы авырулары 13,3%, ашкайнату органнары 10%, нерв системасы 6,6%, органнарның көчсезләнүе 3,3% тәшкил итә (таблица 3).

Мәгълүматлар буенча, Россиядә тәмәке тартучыларның 90% үпкә яман шешеннән, 75% бронхит һәм эмфиземадан, 25% йөрәк авыруларыннан үлә.

Бу саннар барыбызны да уйландырырлык. Мин ышанам, кешеләр киләчәктә үзләренең сәламәтлекләре турында кайгырта башларлар, һәм Россиядә кешенең уртача гомере 57 яшь түгел, ә Япониядәге кебек 81 яшькә җитәр.

Мин, анкетаны тутыртып бетергәннән соң шуны исәпләп чыгардым: бер елда көнгә 1 кап тәмәке тарткан кеше 1 кг га якын дегет йота. Нәтиҗәдә, моның 100% очракта да тире яман шешенә китерүе ачыклнды. Һәм мин шундый нәтиҗәләргә килдем:

1. Әйләнә -тирәдәгеләр тәмәке тартучыларга тискәре мөнәсәбәттә була.
2. Төрле органнар системаларының, беренче чиратта йөрәк һәм баш миенең кан белән тәэмин ителеше бозыла.
3. Хәтер һәм эшкә сәләтлелек акрыная.
4. Кеше авырый: күңеле болгана, йөрәге тигезсез тибә, тамагы һәм ашказаны тынычсызлап тора, ярсып китә, инфаркт булырга мөмкин. Аяклар кисәк авырта башлый.
5. Организмның саклану сыйфатлары көчсезләнә. Тәмәке тартучылар үпкә ялкынсыну, туберкулез, бронхиаль астма белән еш авырый.
6. “Пассив тарту” тәмәке тартмаучылар сәламәтлеге өчен бик куркыныч.

Шундый сорау бирәсем килә: тәмәке тартуны ташлап була микән соң? Бу заралы гадәттән ничек арынырга мөмкин?

Гадәттә, тәмәке тартуны ташлау өчен ике төрле ысул тәкъдим ителә: тәмәке тартудан кинәт тактау яки тарта торган тәмәке санын әкренләп киметә бару. Яшьрәкләр тәмәке тартуны кинәт туктата ала. Ә инде тәмәкене күптән тарткан, йөрәк - кан юлы системасы авыру кешеләргә, шулай ук нерв ситемасы бик үк нык булмаганнарга һәм 60 яшьтән өлкән яшьтәгеләргә тәмәке тартуны әкренләп киметергә тәкъдим ителә . Моның өчен папиросны икегә бүлеп тартырга яки 15 көн буена көн саен тарта торган папирос санын киметә барырга кирәк. Тарта торган папирос 5-6 данәгә калгач, тартуны бөтенләй туктатырга була. Тәмәкене ташлау вакытында йокы качса, тынычсызлык башланса, табиб тәкъдиме белән төрле дарулар кабул итәргә була. Шулай ук тәмәке тартасы килгән саен, төрле дарулы су белән авыз чайкауның да файдасы тия.

Тәмәкене ташлаган кеше яңадан бер генә папирос та тартмаска тиеш, чөнки, ялгышып, тәмәкене бер генә мәртәбә авызга алсаң да , бу - тәмәке тартуны янадан башладың һәм бөтен уңышлар юкка чыкты дигән сүз. Эштә һәм өйдә килеп чыккан төрле хәл, күңелсезлекләр дә тәмәке тарта башларга сәбәп булырга тиеш түгел. Теләсә нинди шартларда да кеше үзендә ихтыяр көче табарга тиеш. Тәмәке тартуны никадәр иртәрәк ташласаң, шулкадәр җиңелрәк. Чынлап та, ни өчен әле тәмәке тартуны ташлау өчен бронхит, йөрәк авырулары, туберкулез яки рак белән авырганны көтәргә соң?

Ә инде укучы балалар, бигрәк тә кыз балаларның тәмәке тартырга өйрәнүләренә килсәк, мин шуны әйтә алам: алга киткән, цивилизацияле, югары культуралы бай илләрдә, интеллигентлы гаиләләрдә күптән инде тәмәке тарту модада түгел, тәмәке тартучыларга, кимсетеп, икенче сортлы кешегә караган кебек карыйлар. Тәмәке тарту шәригать буенча да безнең халыкка ят нәрсә булып тора.

Тикшеренү нәтиҗәләреннән соң мин шуны анладым: минем тема бик дөрес сайланган. Әйе, чыннан да, тәмәке- әкрен тәэсир итүче мина. Тәмәкенең зарары соңрак, әзрәк өлкәнәя төшкәч кенә сизелә. Һәм тәмәке зарары кешене үлемгә дә китерергә бик мөмкин.

Тәмәке төтенендә 1200 зарарлы матдәләр бар. Алар арасында иң куркынычлары никотин, угарный газ CO, аммиак, концероген матдәләр бензоперин, полоний- 210 һ.б. Соңгылары кешедә рак авырулары китереп чыгара, һәр тарткан сигарет кешенең гомерен 5 минутка кыскарта. Тәмәке тартучы үзен генә түгел, үз тирәсендәге кешеләрне дә агулый.

Ни өчен соң үз сәламәтлегебезне үзебез җимерәбез? Һәркем үз сәламәтлеген кайгыртырга тиеш, минемчә. Бүгенге заманда сәламәт яшәү рәвеше алып бару өчен бөтен

мөмкинлекләр  дә бар, фәкать тырышлык, зур ихтыяр көче, үз-үзеңне хөрмәт итү, теләк кенә кирәк!

Йомгаклап шуны әйтәсем килә: тартмасаң - башлама, тартсаң- ташларга тырыш. Дөньяда аннан башка да бик күп күңелле, матур шөгыльләр бар. Сәламәт булуга ни җитә!

## ИГЕЗӘКЛӘР: БЕРТӨРЛЕМЕ ЯКИ АЕРЫЛАЛАРМЫ?

*Гатина Илзирә, 8 сыйныф укучысы,*
*фәнни җитәкче:  Фаляхиева Нурфия Рифат кызы*
*ТР Мамадыш муниципаль районы  "Җөри урта гомуми белем  мәктәбе",*

Дөньяга игезәк балалар туу гадәти хәл түгел, ул шаккату һәм кызыксыну уяткан. Бик тә борынгы карашлар нигезендә төрле халыкларда Игезәкләр турында төрле мифлар һәм мифологик легендалар барлыкка килә. Ярыйсы ук катлаулы бу карашлар системасының килеп чыгышы неолит чорына карый һәм Җиһан-Космос белән бәйле күзаллаулардан килә. Бер үк төсле ике кешенең-Игезәкләрнең Дөньяга килүе Адәм балаларында һәрвакыт ниндидер шик-шөбһә, көчле курку уята торган булган. Чөнки, гади кешеләрнең уйлавынча, әлеге гамәлдә ниндидер илаһи көчләр дә катнашкан булырга тиеш. Шулай булгач, Игезәкләр гайре табигый гамәлләргә дә сәләтле булып, әйтик, кирәк чакта яңгыр да чакыра алалар, дип уйланылган. Икенче бар карашлар буенча, Игезәкләр бу Дөньядагы тормышны, тереклекне барлыкка китерүчеләр. Кайвакыт төрле компромисс карашларга да урын бирелгән: Игезәкләрнең берсе Җир кешесеннән туган булса, икенчесе — алладан яратылган, дип күзалланган. Бүгенге көндә илебездә 70- 80 миллион пар игезәкләр бар дип исәпләнә. Һәр 100 бала тууга 1 пар игезәкләр туры килә. Хәзерге вакытта экологик халәт начараю сәбәпле, сәламәт балаларның тууы проблемасы туа. Икеләтә җаваплылык игезәк балалар туганда арта. Статистика буенча һәр 100 балага бер сәламәт бала туры килә .Соңгы елларда игезәкләр туу артканлыгы күзәтелә. Беренче караштан күренгәнчә, игезәкләр бер- берсенә ошаганнармы, әллә юкмы?

Безнең мәктәпнең 9 нчы сыйныфында игезәк Ибрагимовлар : Ленар һәм Лилия белем ала. Игезәкләр булсалар да характерлары белән аерылып торалар. Нинди кызык феномен! Безнең якын тирә авылларда игезәкләр бармы икән? Игезәкләр бертөрлеме, яки аерылалармы? Ни өчен бер төрле җенесле, төрле җенесле игезәкләр туа? Шушы сорауга җавап эзләп укытучыга мөрәҗәгать иттем. Игезәкләр турында өйрәнү миндә кызыксыну уятты.

Игезәкләр — бер үк анадан бер үк йөклелек чорында, бер үк бала туу вакытында туган балалар. Табигатьтә ике төрле игезәкләр була: бер зиготалы (монозиготалы яки гомозиготалы) һәм икезиготалы (дизиготалы яки гетерозиготалы)

Игезәкләр –табигать могҗизасы. Ике (яки күбрәк тә) бер-берсенә ике тамчы сыман охшаган кеше гел игътибарны яулап тора. Ләкин ике 100% бертөрле тамчы булмаган сыман, ике бертөрле игезәк тә була алмый. Беренче карашка алар бертусле күренә. Алар гел бер-берсеннән аерылалар.

Әйе, бер мәртәбә генә кешеләрне күрсәң, аермасын табырга авыр, ә менә алар белән озак аралашсаң, аермалары шундук күренә. Игезәкләр дигәч, без бер-берсенә ике тамчы су кебек охшаш парларны күз алдына китерәбез.
Ләкин бездәгеләр бер-берсенә бик үк охшап бетмәгән, апалы-сеңелле, яки абыйлы- энеле шикеллерәк, туганннарча охшаганнар. Урысчалап әйтсәк, "двойняшкалар". Аларның берсе гәүдә буенча тулырак, икенчесе ябыграк, төскә-биткә дә икесе ике төрле, характерлары белән дә бик нык аерылалар, хәтта кан группалары да ике төрле.

Игезәкләр күп җирдә бар, диярсез. Әйе, бар икән... Мәсәлән, Украинаның Виноград районы "Великая Кононь" авылында 50 елга 54 пар игезәк булуы интернетта

урнаштырылган. Алар бу хәлне изге су чыганагы белән бәйлиләр. Ростов өлкәсе Денисовка авылында 500 кешегә 19 пар игезәк туры килә. Болары яшәгән җирләренең уңдырышлылыгы яхшы булуы белән аңлаталар.

Игезәкләр бер күкәй күзәнәктән (близнецы), төрле күкәй күзәнәктән (двойняшки) булалар. Төгәл игезәкләр(близнецы) бер күзәнәк икегә аерылып, бер үк соңгылыкта үскән балалар.Фән дә бер күзәнәкнең ни сәбәпле икегә аерылуын аңлата алмый. Двойняшка – игезәкләр икесе ике төрле күзәнәктән ярала, бу яралгыларның һәркайсының үз соңгылыгы була.

Хатын-кызларның игезәкләр табу ихтималлыгы 30-40 яшьләр арасында зур була. Әгәр анның әбиләрендә игезәкләр булса, шулай ук шанс зур. Игезәк балалар тууның нәселдәнлеге әни ягыннан күчә. Соңгы вакытта фән эти ягыннан булырга мөмкинлеген дә раслаган . Һәм алар беренче бала буларак түгел, инде бүтән балалары булган хатын-кызларда очрый икән.

Близнецы- игезәкләр һәрвакыт бер җенестән,аларның күзләре, чәч төсләре , борын формалары бертөрле була.

Двойняшки- игезәкләр бер-берсенә бик үк охшап бетмәгән , икесе ике җенестән булырга мөмкин.

Игезәкләр – кешеләрнең игътибарын үзләренә җәлеп итәләр, чын табигать могҗизасы. Аларны өйрәнү нинди кешеләрнең игезәкләр категориясенә керүен, аларның аерымлыкларын ачыкларга ярдәм итә.

Нәтиҗә ясап шуны әйтергә кирәк, тышкы яктан охшаш булсалар да, игезәкләрнең эчке дөньялары төрле, һәркайсының үз үзенчәлекләре бар.

## АВЫЛДА УМАРТАЧЫЛЫК БЕЛӘН ШӨГЕЛЬЛӘНҮ ФАЙДАЛЫ ХЕЗМӘТ

*Гильмуллин Фәнис, 8 нче сыйныф укучысы,*
*фәнни-җитәкче: Сибагатуллин Малик Тимерхан улы*
*ТР Балтач муниципаль районы “Бөрбаш урта мәктәбе”*

Кешеләр үзләренең яшәү дәверендә һәрвакыт бал кортлары белән тыгыз бәйләнештә. Археологлар мәгълүматларына караганда , умарта кортлары Җирдә моннан 40 млн. еллар элек булган. Галимнәр Франциядә өченче катламнардан ташка әверелгән умарта корты табалар. Алар шөпшәләрнең үзгәрүеннән килеп чыккан. Бал кортының ватаны дип Көньяк Азия санала. Кешенең бал корты продуктларын моннан бик күп гасырлар элек үк кулланыла башлаганлыгы мәгълүм. Испаниядәге Үрмәкүч мәгарәсендә (“Паучья пещера”) б.э.к. XV-X гасырларда ук таш кыяга төшерелгән рәсем моның бер дәлиле булып тора.

Анда лианалар буйлап үрмәләп менеп, кыргый кортлар оясыннан кәрзиненә бал салучы хатын сурәтләгән. Аңа якынча 57 мең ел.

Борынгы чыганаклардан алынган мәгълүматлардан күренгәнчә, Һиндстанда моннан 5-7 мең еллар элек үк балның һәм тома балавызның(прополисның)файдалы үзлекләре билгеле булган.

Борынгы Кытайда балны төрле авыруларга каршы дару буларак кулланганнар һәм корт чактырып дәвалауны да киң файдаланганнар. Борынгы Мисырда бал белән күз авыруларын, яралы һәм пешкән урыннарны дәвалаганнар.

Аристотель, Гиппократ, Вергилий, Демокрит, Пифагор һ.б.акыл ияләре бал ашаган кешенең гомере-озын, акылы-саф, ихтыяры нык була дип исәпләгән.

Россиядә умартачылык белән электән шөгыльләнә башлаганнар. Пётр1нең Европа белән элемтәсе көчле булганлыктан, россиялеләр башка илләргә балавыз чыгара башлаганнар. Бал корты элек – электән кешенең юлдашы, шуңа күрә экиятләрдә, легендаларда, сыналмышларда аңа дан җырлаганнар.

Бал корты гаҗәеп бәләкәй зат. Җирдә бал кортларының 20 мең төре билгеле. Арктикадан кала алар барлык континентларда да яшиләр.

Бәләкәй генә бал корты күпме бал ясый ала соң? 100 г.бал ясау өчен, аңа 46 мең км. юл үтәргә кирәк. Бу шулай ук җир шарын экватор буенча әйләнеп чыгу.

Бал корты – ис сизү чемпионы. Кешегә караганда исне 1000 тапкыр күбрәк тоя, чәчәкләр исен 1 км. ераклыктан ук сизә башлый. Көнгә 1 бал корты 7 мең чәчәккә куна.

Умартачылыктан туклануның иң кыйммәтле һәм сәламәтлек өчен бик файдалы булган бал һәм промышленностьның күп төрле тармаклары өчен кирәкле балавыз продуктлары алудан тыш, умарта кортлары, үсемлекләрне серкәләндерудә катнашулары белән авыл хуҗалыгының күп кенә төп культуралары уңышын күтәрүгә шактый зур йогынты ясыйлар.

Үсемлекләрне серкәләндерудә умарта кортларыннан файдалану нәтиҗәсендә, җиләк-җимеш бакчаларының, карабодай һәм көнбагыш чәчүлекләренең уңышы 50-60 процентка, эспарцет һәм кызыл клеверның орлык уңышы 2-3 тапкыр арта. Умартачлылык белән шөгельләнү ул гаилә керемена дә зур өлеш кертә. Бакчага ямь өсти, күңел тынычлыгы бирә.

Умарта кортлары — гаҗәеп эшчән, төгәл һәм чисталыкны ярата торган җан ияләре. Кешедән тир, аракы һәм башка исләр килсә, алар аны ачуланып чага башлыйлар. Ялкау, шапшак, эчәргә яратучы кеше, әлбәттә, умартачы була алмый.

Умарта кортының башы зур, ул төкләр белән капланган, башының ян-якларында берәр катлаулы күз, ә алар арасында өч гади күзчек урнашкан. Алда ян-якка бөгелеп торган ике озын мыекчасы бар. Бал кортларының 6 аягы бар. Бу аяклар аңа йөрер өчен генә түгел, ә төрле эшләр башкару өчен эш коралы булып та хезмәт итә. Аяклары белән чәчәк серкәсе, прополис җыя.

Кортларның дүрт канаты була: икесе алгы, икесе арткы. Алар шуның белән бик яхшы очалар. Нектарга очканда да, бер минутка бер километр тизлек белән очалар.

Кортларның бөтен тәне йон белән капланган. Аларны ул кыш көне салкыннан саклый.

Умарта кортлары – күмәк тереклек итә торган бөҗәкләр, алар зур семьялар булып яшиләр. Бал кортының бер күчендә меңләгән эшче корт, зуррак бер ана кортлар һәм аз санда ата кортлар, соры кортлар була. Ана корт җәй буена күкәй сала, һәм шул рәвешле, күч сан ягыннан тиз арта. Эшче кортлар – болар җитлекмәгән ана, алар төрле эш башкаралар: кәрәзләрне чистарталар, лечинкаларны ашаталар, ояны саклыйлар һәм бал табалар.

Карт ана корт, яшь ана корт чыгар алдыннан берникадәр эшче кортлар белән бергә, умарта оясын ташлап чыга – шулай күч аеру башлана. Очып чыккан умарта күче, ана корт тирәсенә йомгак кебек сырышып агач ботагына сарыла. Аны капчыкка сыпырып төшереп, яңа умарта оясына күчерәләр.

Умарта корты нектарга бай чәчәкләр эзләп тапкач, оясына кире очып кайта. Ул корсагын боргалап кәрәзләр өстендә әйләнгәли башлый. Аларның болай “биюе” умарта кортлары өчен сузсез “сөйләшү” хезмәтен үти. “Бию” хәрәкәтләренә карап, кортлар табыш артыннан кайсы якка һәм нинди ераклыкка очарга кирәклеген беләләр. Табышлы урынга очып килгәч, умарта кортлары беренче кайсы чәчәк исен алып кайткан булса, шул чәчәккә килеп куналар.

Кортчылык продуктлары кеше тарафыннан, беренче чиратта, сәламәтлек өчен файдалы һәм туклыклы булганга , шулай ук бизәнү сәнгатендә киң кулланыла.

Бал кортлары туклыклы һәм шифалы бал бирәләр. Балны йөрәк – кан тамырлары, үпкә, күз авырулары, шулай ук яраларны дәвалау өчен кулланалар. Ул бавыр, бөер, ашказаны эшчәнлеген яхшырта. Балның 90% ы туклануда кулланыла.

Ул конфет, прәнник, салат, бәлеш, торт, куе ширбәт, төнәтмә кебек ризыклар составында кәндәлек һәм бәйрәм өстәленә килә. Бу –балның шифалы һәм диетик өстенлекләрен ассызыклый. Шикәрне табуы ансатрак һәм арзанрак булса да, балга көндәшләр юк. Ул элек ничек дәрәҗәле булса, бүген дә шулай, киләчәктә аңа хөрмәт әле тагын да артыр.

Чәчәк серкәсен, ягъни “перга”ны, медицинада балаларда азканлылыкны дәвалау өчен кулланалар. Ул кандагы эритроцитларны һәм гемоглабинны күтәрә. Ана корт сөте туклыклы

һәм кыйммәтле матдә. Ул майларга, витамин нарга һәм аксымнарга бай. Организмда матдәләр алмашын яхшырта.

Прополисны – суык тигәндә һәм авыртуны басуда кулланалар.

Бал кортының агуы, кеше организмында иммунитетны ныгыта, ревматизмны дәвалый. Кишергә караганда, балавызда витаминнар 400 тапкыр күбрәк. Бал кортларына кыйммәтле продукт җитештерү чыганагы итеп кенә карау дөрес булмас. Ник дигәндә, бу тырыш бөҗәкләр ,чәчәктән-чәчәккә кунып, үсемлекләрне серкәләндерә , моның белән уңышның артуына һәм сыйфаты яхшыруга булышлык итә. Бал кортлары булмаса, авыл хуҗалыгы карабодай, көнбагыш, җиләк-җимешләрдән меңәрләгән тонна уңышны кимрәк алыр иде. Борын-борын заманнарда ук балны Алла тарафыннан Җиргә кеше бәхетенә җибәрелгән бүләк дип санаганнар.

Умарта кортлары тормышыннан кешеләргә бик күп үрнәк алырга була. Аларның оясын ачканда ук хуш ис килеп тора. Бу сулыш юлларына шифа бирә. Гомумән, бал кортлары белән бәйләнгән һәрнәрсә дә кешегә дәва һәм шифа китерә. Мәсәлән, бал, балавыз, умарта «сөте», чәчкә серкәсе, прополис – аларның барысын да чирләрне дәвалаганда кулланалар. Хәтта үлгән умарта кортларыннан да дару ясыйлар. Умартачылык продукцияләре нигезендә хәзер бик күп дарулар әзерләнә. Медицина өлкәсендә хәтта аерым дәвалау системалары барлыкка килде. Шуларның берсе — кортлардан чактыру ( Апитерапия) . Бер бал корты бер көн эчендә 20 мең чәчкәгә куна. Ә менә биш йөз кортның җыйган балы бер кашыкка сыя. Бер ана корттан 50 меңгә якын умарта кортлары үрчеп, бер гаилә булып яшәүләре - үзе бер могҗиза. Алар бүгенге көнне генә түгел, киләчәкне кайгыртып, зур бер тату җәмгыять булып яшиләр. Һәр эшче корт үз вазыйфасын төгәл үти һәм вакытында башкара. Бер ана корт тәүлегенә 2 - 3,5 мең йомырка сала. Ул үз оясындагы барлык кортларны берләштереп торучы көчкә ия булса да, бөтен булган проблемалар “җәмгыять шура”сында кумәкләшеп хәл ителә. Яңа яралган кортлар бер атна оя эчендә генә хезмәт итәләр. Аннан соң аларның һәрберсе үз өстенә йөкләнгән вазифаны аерым башкара башлый. Күзәтүче, сакчы, бал ташучы, чистартучы, яңа яралганнарны ашатучылар, ана һәм ата кортлар – аларның барысы да үз эшләрен төгәл һәм җиренә җиткереп башкаралар.

Безнең гаилә бик күптәннән бирле кортчылык белән шөгелләнә. Әтиемнең бабасыннан башлана бу шөгел. Әти башка чыкканда аңа бабай 5 баш корт биреп чыгарган. Әтигә инде 53 яшь! Хәзерге вакытта 15-20 баш умарта корты тотабыз. Елның елында даими табыш алабыз. Табышның сере дә бар: безнең авылыбыз тирәли урман. Урманда 5 кортлык бар (700 башлап умарта). 10 хуҗалык авылда бал кортлары асрый 150 башлап умарта исәпләнә. Кортларның аеру вакыты җиткәндә, эти белән урманга чолык (эче куышланган баш башлары ябык, кортлар очып керү өчен 2 тишеге булган юкә яки чыршы агачы) яки фанерадан ясалган жиңел тартмалар илтеп элеп куябыз.

Чолыкларны теләсә нинди агачка куймыйбыз - чыршы, юкә, усак агачларына эләбез. Алар әлбәттә юан кәүсәле булырга тиеш. Кортлар күч аерыр алдыннан разведчик кортлар яңа күч өчен оя эзли. Элек табигатьтә алар куыш агачларда оялаганнар. Ә куыш агач юан агачта гына була, бигрәктә мин алда атаган агачларда. Шуңа күрә алар шундый агачлар янына килә, чолыкны күрә, куыш агач таба. Һәм кайтып яңа оя табуы турында хәбәр бирә. Бу ояны тикшерергә умартадан шактый гына котрлар килә (чолык тирәсендә тикшереп очып йөриләр). Урмандагы агачка сарган булсалар иртәнге 10 тирәсендә чолыкка күчеп керәләр. Әгәрдә оясы янында гына сарган булсалар төштән сон, 2-3 тирәсендә килеп керәләр. Моны узебезнең күзәтеп торган булды. Хәтта шундый очрак булды, күч куыш агач эченә кереп бетә алмады, тышына сарды. Без ул кортларны 2 тубалга җыеп , калганнарын оясы белән алып кайттык. Күчнең авырлыгы 12 кг иде. Чолыкка кергән корт берничә сәгатьтән соң юл алып оча башлый. Корт кергән чолыкны кичке сәгать 9-10 соң барлык кортлар кереп беткәч алып кайтабыз. Моны шул көнне үк башкарырга кирәк. Чөнки кортлар узләренең ояларына ияләшә, хәтерендә калдыра. Әгәрдә аларны берничә көнгә калдырсаң, алып кайтып умартага япкан кортлар шушы урынга кайтачак. Бу очракта яңа күчне 4-5 км. ераклыкка урнаштырырга мөмкин. Ясаган чолыкның стенасы 3-4 см калынлыкта булырга тиеш. Юка

стеналысына бик сирәк керәләр. Чөнки аларның кыш та чыгасы бар. Әти моны тәҗрибә юлы белән эшләп карады. Фанерадан, 2 сантиметрлы тактадан ясап, агачтан ясалган чолыклар белән янәшә куйды. Ләкин аларына кортлар кермәде. Корт тоткычның эченең күләме дә кечкенә булса, кортлар килми. Бик сирәк, бик кечкенә күч булса гына керәләр. Кимендә 50-75 см куб булырга тиеш.

Чолыкны куяр алдыннан аның эченә кәрәз калдыклары салып куябыз. Әти ясаган чолыкларны урман кырлатып 4 км аралыкка куеп чагабыз. Аларны алдан элгән булсан, шөпшә, бусан , хәтта тиен дә кереп ояларга мөмкин. Андый ояга кортлар керми. Узган елны шулай итеп 16 корт күче алып кайттык. Бер көнне 2-3 күч кергән көннәр дә булды. Аларны алдан әзерләнгән ояга ябабыз. Корт күчләре күп булса ояга өскүтәртмә (корпус) дә куела. Умарта эченә 1-2 уллы кәрәзле, ә калганнарына ясалма кәрәзле рамнар куела. Чолыклардан кортларны ояга күчергәндә йөгертмә тактадан файдаланабыз. Аларны кушар алдыннан сугышмасыннар өчен, балдан ширбәт суы ясап сарымсак ,бөтнек исе кертеп бөркибез. Шулай иткәч барлык кортлардан да бертөрле ис килә, сугышу булмый. Йөгертмә тактадан керткәндә аналарын тотып калырга да була. Ширбәт суы бөркегәч алар оча алмый башлый. Иң көчле күчнең анасын ана читлегенә куеп умарта эченә урнаштырабыз. Кортлар юл алып оча башлагач, ананы җибәрәбез. Умартадагы күчнең авырлыгы 8-10 кг җитә. Умартада яшь кортлар булмау сәбәпле, барысы да кәрәз ясарга керешә (кәрәз алуны арттыру, яна кәрәзләр булдыру ). Шундый ук ысул белән көчсез ояларны да чолыктагы күч белән көчәйтәбез. Ләкин элекеге умартадагы кортларны икенче умартага күчереп урнаштырабыз. Болай эшлэгэндэ ике корт та яна чит умартага керэ икесе арасында сугышу булмауга да китерэ . Умартадагы күч күп булган саен бал җыю да арта. Бу эшләр юкә чәчәк атыр алдыннан була. Юкә чәчәге аткач корт аеру да туктала. Безнең авылда төп табыш юкә чәчәгеннән, болынлыклар аз. Күмәк хуҗалык басуларына бал бирә торган культуралы үсемлекләр чәчелми. Шунлыктан бу ысул безгә бик кулай. Болыннар аз булгач чәчәкләр дә аз. Кортлар тиз үрчи алмый. Табыш вакытына 5-6 кг лы күчләр кортлыкларда өчтән бере генә була. Аз күч булганда бал бик аз җыела. Узган ел бал аз булды диделәр. Ләкин бездә мул булды. Корт күчләрен арттыру аркасында.

Очып чыккан күчләр белән төрле авырулар килергә мөмкин дигән фикерләр бар. Әти: "Авыру корт үрчи алмый, күчле корт кына аера. Минем купеллык тәҗрибәдә аныдй очрак булмады" . -ди.

Эле без тоткан кучлэрне умартага гына ябып калмыйбыз ,алдан кергэннэрен чолыгы белэн калдырабыз (кучнен кочен улчэп белэбез). Кочле куч козгэ 30-35 кг кэрэзле бал ,2-3 кг сарышын (перга) ,томабалавыз(прополис) белэн дэ безне сыйлый ала.

Бал һәм балавыз чыгару — борынгы кешеләрнең хезмәте. Элек электэн Рәсәйнең бай урманнарыннан махсус ясалган яисә табигый барлыкка килгэн агач куышларыннан бал җыйганнар. Ул вакытта кыргый кортлардан бал алганнар. Тора бара урманнар кими башлагач, кешеләр куыш агачларны кисеп бал кортларын йортка якынлаштырганнар яисә кортларга яшәү шартлары булган урманнарга куйганнар. Беренче рамлы умартаны 1814 нчы елда Петр Прокопович уйлап тапкан, ә 1851 нче елда Лангстрот дигән әфәнде бүгенге кондә куллана торган умартаны уйлап чыгарган. Бу яңа умартаның бал алу микъдары да шактый арткан.

Татарстанда умартачылыкның азык базасы урман зонасында бал бирүче агач токымнары (юкә, өрәңге, тал һ.б.), шулай ук вак агачлары киселеп, үсентеләр басып киткән диләнкеләрдәге, янган урыннардагы, сирәклекләрдәге, ачык аланнардагы, сазлыклардагы һәм агачлары череп ауган мәйданнардагы чәчәкле-җиләкле үсемлек-куаклыклар (кипрей, кура җиләге, кара җиләк, зонтиклылар семьялыгы үсемлекләре һ. б.) белән билгеләнә. Монда экологик чиста умартачылык продуктлары (бал, серкә, балавыз һ.б.) алу өчен уңай шартлар бар. Безнең шартларда төп бал бирүче - юкә агачы. Юкәлекләрдән ел саен 50 мең тоннадан артык бал алына. Бал бирүче кыр культураларына Татарстанда 4% чәчүлек туры килә. Алар арасында төп урынны рапс чәчүлекләре алып тора, аннан соң карабодай һәм орлык өчен чәчелә торган күпьеллык кузаклы культуралар.

Бал бирүче үсемлекләрнең төп массасының чәчәк атуы һәм умарталарга бал кортларының нектар ташуы буенча Татарстанда умартачылык сезонын язгы, җәйге һәм көзге чорларга бүлеп була. Иртә яз чоры бал кортларын кышлаудан чыгарганнан башлап 16 майга кадәр бара, һәм бу чор бал бирүче үсемлекләрдән талчалар семьялыгына керүче агачларның: өрәңге, җиләк-җимеш бакчаларының чәчәк атуы белән сыйфатлана. Язның бу чорындагы нектар запасы бал кортларына һәр гаилә башына 10 кг бал җыярга мөмкинлек бирә. Язның икенче яртысына (16 майдан 16 июньгә кадәр) бал бирүче бу үсемлекләр чәчәк атуларын тәгәллиләр. Аларга алмашка урман кура җиләге, болын үсемлекләре һ.б. чәчәк ата башлый, ләкин әле алар бу вакытта массакүләм төс алмый. Шуңа күрә Татарстан шартларында җәй башында бер ай чамасы вакытта бал җыярдай чәчәкләргә кытлык булла

16 июньнән 6 июльгә кадәр дәвам иткән иртә җәй чорында болыннар һәм көтүлекләрдәге төрле үләннәр, рапс, люцерна, вика, эспарцет, тәкәмөгез, урман кура җиләге һәм башка бал үсемлекләре чәчәк ата. Бу чордагы табыш югалтулардан күбрәк була, бал корты гаиләләрендә бал запаслары туплана башлый.

Татарстан шартларында җәйнең икенче яртысында (чама белән 6 июльдән 6 августка кадәр) табигый бал бирүче үсемлекләрнең дә, чәчеп үстерелә торган культураларның да төп массасы чәчәк ата. Республиканың төп бал ресурсларыннан саналган юкә белән карабодай да шушы чорда чәчәк ата. Сезон өчен теоретик мөмкин булган нектар запасының 84%ы шушы чорга туры килә. 6 августтан көзге чор башлана. Ул бал бирүче культураларның (карабодайның, соң чәчелгән көнбагышның, икенче чираты өлгергән күпьеллык үләннәрнең, кыргый үсемлекләрнең) чәчәк атуы тәгәлләнгәнче бара. Сезонлык бал запасы бал бирүче үсемлекләрнең категорияләре буенча түбәндәгечә бүленә: авыл хуҗалыгы чәчүлекләре 9%, болын һәм көтүлекләр, урманнар, ташландык җирләр, сазлыклар 91%.

Татарстан шартларында бал җыю өчен иң кулай вакыт булып июльнең икенче бишкөнлеге санала. Кама аръягы районнарында бал җыю сезоны якынча 3—4 көнгә соңрак башлана. Умарталарның көнлек артымы 0,5 кг нан да кимү — төп бал җыю тәмамлана дигән сүз. Бу чор якынча 23 июльгә туры килә. Республикада төп бал җыю вакыты 17 көн чамасы дәвам итә.

Бал кортлары борынгы заманнардан ук кешегә файда китерүче булып саналган. Кеше бал кортына уңайлы булган оя ясаган, ә кортлар исә кешене бал һәм балавыз белән тәэмин иткән. Ул вакытта бал шикәрне алыштырган, ә балавыз яктылык чыганагы материалы буларак файдаланылган. Бал һәм балавыз белән кеше налоглар түләгән.

Авылда яшәп һәм тырышып, дөрес юнәлештә хезмәт итсәң , күп нәрсәгә ирешеп, яхшы табыш алып булуына ышанам һәм сезгә умартачылык буенча яхшы табыш алып булырлык кортларны чолык белән тотып үрчетү юлын тәкъдим итәм. Бөрбаш авылы җирлегендә умартачылык белән шөгыльләнү өчен барлык уңай шартлар да бар. Без моның шулай булуына визуаль күзәтүләр һәм сораштырулар аша да инандык. Аерым кортлыклары булган хуҗалыклар һәм оешмалар булу шулай ук моңа дәлил булып тора. Умартачылык эшен башлаган шәхесләргә артык чыгымнар чыгармыйча умарта санын арттыру һәм табыш алу өчен уңайлы юл дип саныйм.

## ЯДЕГӘР АВЫЛЫ ҖИРЛЕГЕНДӘ ҮСҮЧЕ ДАРУ ҮЛӘННӘРЕ

*Мөбәрәкова Динә, 10 нчы сыйныф укучысы,*
*фәнни җитәкче: Нәбиева Рәмзия Мәүлит кызы*
*ТР Кукмара муниципаль районы “Ядегәр авылы урта гомуми белем бирү мәктәбе”*

Элеккеге заманда барлык даруларны да табигый матдәләрдән алганнар. Бу үсемлекләрнең яки аларның төрле өлешләренең төнәтмәләре булган. Алар кеше организмы тарафыннан яхшы үзләштерелгәннәр. Тора-бара химиклар үсемлекләрдән тиз нәтиҗә бирә

торган матдәләр алуга ирешкәннәр. Үсемлекләрдән дарулар ясый башлаганнар. Ә соңрак галимнәр авыртуны басарга сәләтле ясалма көчле дарулар уйлап чыгарганнар. Ләкин бу ясалма дарулар организмга файда гына китермиләр, зыян да ясыйлар.

Авыру җиргә файда өчен эчкән дару башка сәламәт органнарга күпме дә булса зыян салырга мөмкин. Шуңа күрә даруларга бик сак карарга киңәш ителә. Бүгенге көндә атлаган саен даруханәләрне очратырга була. Алар чит илләрдән кертелгән кыйммәтле синтетик препаратлар белән тулы. Шул ук вакытта бик күп авыруларны төрле үләннәр белән дә дәвалап булу мөмкинлеге кешеләргә таныш. Теманың актуальлеге шунда чагыла.

Фитотерапия – төрле авыруларны күп үсемлекләрдә була торган актив матдәләр (алкалоидлар, глюкозитлар, органик кислоталар, тозлар, витаминнар, сумалалар һ.б.) кулланып дәвалау ысулы- борынгы һәм бүгенге медицинаның нигезен тәшкил итә.Ул дару үләннәренә карата сакчыл караш тәлап итә. Дару үләннәрен бик күп дип санасак та, аларның кайберләре бетү ягына бара. Дару үләннәрен еркычларча куллану табигый байлык запасын кимүгә китерә. Атаклы дару үләннәре белгече, аларның организмга тәэсирен яхшылап өйрәнгән Адель Федоровна Геммерман: «Халык медицинасы юкка чыга, ә аның белән бергә гасырлар буена беркая да язылмаган, тупланмаган халыкның байлыгы бетә”, дип язган.

Бу фәнни эш белән шөгыльләнгән вакытта күп кенә әдәби чыганакларга тап булдык. Иң әһәмиятлеләре итеп Новиков В.С., Губанов И. А. “Школьный атлас-определитель высших растений, Плешаков А.А. “Зеленые страницы”, Сафонов Н.Н. «Домашняя энциклопедия растений» китапларын атарга мөмкин.

Дәвалау һәм профилактикалау максатыннан халыкта, медицинада кулланылучы үләннәр группасын **дару үләннәре** дип атыйлар. Дару үләннәрен халык медицинасы киң файдалана. Җир йөзендә нинди нинди генә дару үләннәре юк! Безнең илдә 500дән артык дару үләне үсә. Барлык даруның 40% ын дару үләннәреннән ясыйлар.

Дару үләннәрен дөрес җыя белергә кирәк. Автомобиль юлларына, завод-фабрикаларга якын җирдән җыярга ярамый. Белмәгән үсемлекләрне җыюдан сакланырга кирәк, агулы үсемлек булырга мөмкин. Әгәр үсемлекнең барлык өлешен дә файдаланасың икән, чәчәк аткан чорда җыярга кирәк. Яфракларын чәчәк атар алдыннан, ә тамырларын көз көне үсемлек шиңгәч җыялар. Үсемлекнең җир өсте өлешен көн, көн коры булганда чәчәк ату чорында җыялар. Орлыкларын, җимешләрен тәмам өлгереп җиткәч җыеп киптерәләр. Табигатькә зыян китермичә җыйганда, тиешенчә киптергәндә һәм саклаганда, шулай ук куллану кагыйдәләрен истә тотканда, алар кешегә бик күп авырулардан дәваланырга, сихәтләнергә ярдәм итә. Үсемлекләне төбе-тамыры белән йолкымагыз. Дәвалану өчен кирәкле өлешен генә кисеп алыгыз.Дару үләннәрен коры көннәрдә җыялар. Ә тамырларын балчык юеш булганда да казып алырга була. Алар – капчыкка, ә яфраклар һәм чәчәкләр киң сумкага яки кәрзингә җыела. Җыелган үсемлекләрне тыгызларга, вакларга ярамый. Болай эшләгәндә алардагы файдалы матдәләр таркала.

Дару үләннәрен җыеп, 2-3 сәгать үткәннән соң ук, аларны киптерергә куегыз. Үсемлекләрнең күбесе күләгәле яки җиләс урында чиста кәгазь яки тукыма өстенә юка гына җәеп киптерелә.

Киптерелгән үләннәр кәгазь пакетларга яки катыргы тартмаларга тутырыла һәм коры, чиста урында саклана.

Үсемлекләренең дәвалау үзлекләре бик борынгы заманнардан ук билгеле. Казу эшләре вакытында табылган үләнәрне кайнату, ышку өчен кулланылган предметлар неолит чорына туры килә. Беренче дару үләннәре турындагы язмалар безнең эрага кадәр 6 мең ел элек яшәгән шумерларга карый. Иракта яшәгән шумерлар чиста дару үләннәрен кулланганнар һәм алардан төнәтмә, порошоклар ясаганнар.

Дару үләннәренең серләрен Борынгы Египтта, Индиядә, Кытайда яхшы белгәннәр. Шулай ук Грециядә, Римда һәм Русьта үләннәрне дәвалау чарасы буларак киң кулланганнар. Хәзерге көндә дә дару үләннәре медицинада кулланыла.

Халык кабилә булып яшәгән чорлардан ук дәвалау чаралары турында мәгълүматләрне бер буыннан икенче буынга күчергәннәр, ә соңрак бу аерым гаиләләрнең байлыгына

әверелгән. Безнең эрага кадәр 2 меньеллыкта Вавилон ханлыгындагы халык дару үләннәрен киң кулланалар. Бай һәм күптөрле Вавилон флорасы – күп дару үләннәренең Ватаны булып исәпләнә. Мәсәлән: төче тамыр (солодка), тилерткеч (дурман), тиле-бәрән орлыгы (белена), җитен (лен). Алар кояш нурларының кайбер дару үләннәренең шифалы үзлекләренә тискәре йогынты ясавын да белгәннәр. Шуңа күрә аларны күләгәдә киптерәләр, ә кайберләрен төнлә генә җыйганнар.

Дару үләннәрен куллану буенча алга киткән илләргә Борынгы Грецияне кертеп була. Безнең эрага кадәр 460-377 яшәгән Гиппократ дару үләннәренең сокларында кеше организмнына уңай тәэсир итә торган актив матдәләр барлыгын раслый. Аның язмаларында 236 төр үсемлеккә аңлатма бирелгән. Гиппократ “Медицина ул - табигатьнең дәвалау үзлекләрен кабатау сәнгате” («Медицина — есть искусство подражать целебному воздействию природы») , дип әйткән.

Борынгы Римда яшәгән яшәгән практик, теоретик Клавдий Гален табигать фәннәре, философия турында 400 инша язган. Аның яртысы медицинага, авыруларның килеп чыгу сәбәпләренә, дәвалау чараларына, методларына багышланган.

Көнчыгыш халык медицинасы да борынгыдан билгеле. . Ә безгә исеме экиятләрдән билгеле булган күренекле таҗик табибы Әбугалисина 900 гә якын үсемлекнең файдасы турында яза.

Кытайда табылган үсемлекләр турындагы китап (Бень Цао) б.э.к 2600 еллар белән даталанган. Китапта 900 төр үсемлеккә тулы тасвирлама, аларны куллану турында мәглүмат бирелгән.

Тибет медицинасын турындагы “Чжут-ши” трактында дәвалаучылар кулланган 8 төр дару матдәсе турында язылган. Бу- төрле минераллар (күкерт, акбур, балчык, корым), хайваннардан алынган матдәләр (май, ит, тире, мөгез, үт сыекчасы). Ләкин дәвалау матдәләрен күпчелеген үсемлекләрнең сокларыннан алганнар.

Урта гасырларда Көнбатыш-европа табиблары антик медицина әдәбиятын кулланганнар. Исемлеккә якынча 1000 төр үсемлек кергән. Европа даруханәсе гарәпләр үрнәге буенча төзелгән. 9-10 гасырларда Галенның, Деоскаридның үләннәр турындагы китабы тәрҗемәсе испан, немец һәм француз телләрендә барлыкка килә. Нәтиҗәдә, Европа медицинасына төрле илләрнең барлык дару үләннәре керә.

Россиядә беренче аптека, Явыз Иван җитәкчелек иткәндә, 1581 елда Мәскәүдә ачылган. Ул Кремль палатасында урнашкан һәм патша сараена хезмәт иткән.

Дару үләннәрен киң куллану Алексей Михайлович патшалык итү чорына кагыла. Аптека палатасы аптека боерыгына үзгәрә һәм анда дару үләннәрен җыю белән шөгыльләнергә кушылган була.

Россиядә иң беренче аптека мәктәбе Мәскәүдә 1654 елда оешкан һәм анда даруханәчегә укытканнар. Шул ук елда “Аптека бакчалары” барлыкка килә. Анда дару үләннәрен үрчеткәннәр.

Россиядә Петр беренче “Аптека бакчасы”на нигез салуда бик күп эшләр эшли. Аның указы буенча 1714 нчы елда Петербург шәһәрендә бакча оештырыла һәм анда дару үләнәрен өйрәнү буенча беренче станция барлыкка килә. Хәзерге вакытта бу урында фәннәр Академиясенең ботаника бакчасы урнашкан.

18 нче гасыр ахырында һәм 19 нчы гасыр башында борынгы дару үләннәренә кызыксыну арта. Н. М. Амбодик – Максимович үзенең «Врачебное веществословие» дигән хезмәтен бастыра.

19 нчы гасыр ахырында, 20 нче гасыр башында фән үсеше нәтиҗәсендә үләннәр белән дәвалану икенче планга күчә. Тик шулай да фәнни фармацевтика туктамый, рус терапевтик мәктәпләренә нигез салучылар Г. А. Захарьин, Ф. И. Иноземцев, С. П. Боткин дару үләннәрен авыруларны дәвалау өчен куллануны дәвам иткәннәр.

| **Органнарга тәэсире** | **Үсемлек** |
|---|---|
| Ашказаны-эчәклек тракты | Календула, гөлбадран, бака яфрагы, |

| | |
|---|---|
| | ромашка,гөлҗимеш, лилия, суган, шомырт, лох, тузганак, канлы үлән, кычыткан, мең яфрак. |
| Нерв системасы авырулары | Бөтнек, цикорий, хмель, череда, мелисса |
| Сулыш юллары авырулары | Көнбагыш, кура җиләге, чамбыр, тукранбаш, кычыткан, бака яфрагы,мелисса |
| Дезинфикция чарасы | Календула, череда, гөлбадран, әрем, цикорий, шалфей, чамбыр |
| Кан тамырлары, кан әйләнеше авырулары | Гөлбадран, цикорий, рәйхан, пустырник, гөлҗимеш, тузганак, бака яфрагы |
| Үт куу чаралары | Гөлбадран, әрем, укроп, кукуруз, кычыткан, тузганак, канлы үлән |
| Авыртуны бетерә торган чаралар | Бөтнек, канлы үлән, пустырник |
| Ялкынсынуга каршы чаралар | Ромашка, гөлбадран, меңъяфрак, календула, шалфей, базилик, клевер, кычыткан, кузгалак, бака яфрагы |
| Яра төзәткеч чаралар | Календула, кычыткан, кузгалак, бака яфрагы |
| Кан ясагыч үләннәр | Череда, меңъяфрак, кычыткан, кукуруз, кура җиләге, гөлҗимеш |

Бүгенге көндә дару үләннәре белән кызыксыну арта бара. Бөтендөнья сәламәтлек саклау организициясе мәгълүматларна караганда Җир йөзендәге халыкның 80 % дару үләннәреннән файдалана. Зур дару ясау компанияләре үсемлекләрнең дәвалау үзенчәлекләрен өйрәнүне дәвам итәләр. Дару үләннәреннән ясалган таблеткалар көчлерәк килеп чыгу сәбәпле, алар гел яхшы гына йогынты ясамыйлар. Бер җиргә файда китерсәләр, икенче җиргә зыян салырга мөмкиннәр. Шуңа күрә дару үләннәренең үзләрен куллану бик популяр. Шулай булса да, дару үләннәрен үз белдегең белән теләсә ничек кулланырга ярамый. Үләннәрнең кайсы өлешләрен, нинди дозада кулланырга, кайчан җыярга, нинди авыруларга каршы кулланырга мөмкин булуын бик яхшылап өйрәнергә кирәк.

## ВЛИЯНИЕ РАСТВОРОВ СРЕДСТВ ДЛЯ МЫТЬЯ ПОСУДЫ НА ЖИВЫЕ ОРГАНИЗМЫ

*Садиков Данил, ученик 9 класса,*
*научный руководитель- Файзрахманова Гульфия Фаритовна*
*МБОУ «Соснинская ООШ» Балтасинского муниципального района РТ*

По данным статистики, мытье посуды является у россиян вторым самым нелюбимым домашним делом после уборки квартиры. Но, несмотря на нелюбовь к этому делу, нам приходится мыть посуду ежедневно. И для этого большинство из нас использует синтетические моющие средства, которые позволяют нам быстро и легко отмыть жир и грязь.

Однако, все ли из нас знают, чем мы жертвуем ради эффекта быстроты и легкости при мытье посуды? И все ли из нас знают, что в течение года мы выпиваем около полулитра жидкого моющего средства?

Не верите? Так, для того, чтобы полностью смыть моющее средство посуды, необходимо ее ополаскивать не менее 5 раз. Кто из нас так делает? Я думаю, практически никто. Соответственно, частицы моющего средства с плохо ополоснутой посуды попадают в нашу пищу, а затем и в наш организм.

Химики утверждают, что полностью удалить ПАВ с поверхности посуды удается лишь хромовой смесью или прокаливанием в пламени горелки.

Моющее средство попадает в наш организм с посуды, на котором оно остается.

В желудке находится соляная кислота. Она выполняет важную задачу – позволяет расщеплять белки пищи. Почему же тогда желудок не растворяется под её воздействием? Потому что он покрыт защитной оболочкой из слизи, которая постоянно вырабатывается клетками стенок желудка, которая разрушается под действием СМС.

Значит, если в организм человека попадает СМС с недомытой тарелки, то защитная, отталкивающая воду оболочка вокруг стенок желудка, становится тоньше. Результат – развивается язва желудка.

В состав моющего средства входят поверхностно-активные вещества <ПАВ> (убивают клетки человека), кислоты и щелочи; хлор (вызывает жжение глаз, головную боль, затрудненное дыхание, усталость); отбеливающие вещества; отдушки (используются для того, чтобы отбить неприятный запах самого СМП); ферменты, обеспечивающие удаление трудновыводимых пятен, бактерициды, обезжириватели, стабилизаторы пены и многие другие вещества.

Вот коротенький список заболеваний, к которым ведет ежедневное использование СМП: депрессия, гипертония, нарушение зрения, язвы, рак желудка, аллергия, экзема.

Применение любого средства бытовой химии должно начинаться с изучения данных на этикетке. И чем точнее эти данные, тем достовернее информация. Из этикеток исследуемых моющих средств для посуды мы определили, что: · основным компонентом МС являются ПАВ, но только на этикетке МС «FAIRY» более точно указано процентное содержание ПАВ и их тип; · кроме ПАВ в составе моющих средств имеются красители, стабилизаторы, консерванты, парфюмерная композиция, но не указана маркировка этих веществ, что не позволяет; · большое внимание уделяется на этикетке МС рекламным данным; эффективно удаляет все остатки жира с посуды не только в горячей, но и в холодной воде, легко смывается водой, не оставляя разводов и придаёт посуде блески изумительную чистоту.

- не поражает кожу рук и обладает нейтральным уровнем кислотности рН благодаря своей тщательно подобранной формуле.

Для исследования состава, особенностей применения, адресных данных производителя моющих средств для посуды изучались этикетки средств, указанных при анкетировании пользователей.Как правило, инструкций по мытью посуды никто не читает, но это не освобождает производителя от необходимости нанесения этой информации на этикетку.

Данные исследования приведены в таблице

Состав, свойства и особенности применения моющих средств

| | **Fairy** | **АОС** | **МИФ** | **SORTI** | **Капля** |
|---|---|---|---|---|---|
| 1. Объем/мл | 500 | 500 | 500 | 500 | 500 |
| 2. Срок годности | 18 мес. | 18 мес. | 18мес. | 18 мес. | 24 мес. |
| 3. Состав | 5-15% анионные и неионогенные ПАВ, отдушка, консервант, цитронеплол, лимонен и линалоол. | 5-15% анионные и неионогенные ПАВ, соль этилендиаминтетрауксусной кислоты, ароматизирующие добавки, консерванты | анионные и неионогенные ПАВ, хлорид натрия, лимонная кислота, консервант, парфюмерная композиция, лимонная кислота | Вода, анионные и неионогенные ПАВ, соль этилендиаминтетрауксусной кислоты, ароматизирующие добавки, консерванты, | Вода, ПАВ, хлорид натрия, лимонная кислота, консервант, парфюмерная композиция, лимонная кислота, |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 5.Рекомендации по применению | нанести небольшое количество средства на влажную губку | Несколько капель средства капнуть на влажную губку | Несколько капель средства капнуть на влажную губку | Несколько капель средства капнуть на влажную губку | Небольшое количество средства нанести на влажную губку |
| 6. Меры предосторожности | При попадании в глаза промыть водой | Предохранять от солнечных лучей. Хранить вдали от отопительных приборов. Беречь от детей. При попадании в глаза промыть водой. | Беречь от детей | Предохранять от солнечных лучей. Хранить вдали от отопительных приборов. Беречь от детей. При попадании в глаза промыть водой. | Беречь от детей, избегать попадания в глаза. |

Данные таблицы позволяют сделать следующие выводы:

• При равном объеме моющего средства цена средств не одинакова.

К более дорогим средствам можно отнести «Fairy», «AOC», более дешевыми средствами являются «Миф», « SORTI» и «Капля ».

• Срок годности всех средств почти одинаковый.

• Основным компонентом МС являются ПАВ.

• кроме ПАВ в составе моющих средств имеются красители, консерванты, парфюмерная композиция, но не указана маркировка этих веществ, что не позволяет сделать вывод о их безопасности для человека.

• На упаковках не указано точное количество средства, необходимого для использования. Лишь написано «нанесите небольшое количество на губку или на посуду» или «капнуть несколько капель…».

• Практически все средства, кроме «Fairy» содержат предупреждение: «Беречь от детей» и описывают действия при попадании средства в глаза.

• Большое внимание уделяется на этикетке МС рекламным данным: производители указывают, что все средства эффективно удаляют жир не только в горячей, но и в холодной воде, легко смываются водой, не оставляя разводов. На этикетке средства «Fairy» указано, что соответствует стандарту РФ по смываемости с посуды.

Химические особенности моющих средств для посуды исследовались в три этапа: а) определение pH растворов моющих средств для посуды; б) влияние растворов моющих средств для посуды на протекание процессов коррозии железных.
в) влияние растворов моющих средств для посуды на биологические объекты

Тик бар да алай чәчәкле-чуклы гына түгел шул. Сыер савучы – бик авыр, катлаулы, зур игътибар һәм көч сорый торган профессия! Бу хезмәттә хайваннар белән аралаша белергә дә, тырыш, сабыр, таләпчән булырга да кирәк. Иртәнге 3тә шалтыраучы будильникка үзеңне уяту, ай-һай, бер дә җиңел түгел. Бөтен авыл изрәп йоклаганда, йомшак һәм җылы юрган астыннан да чыгасы килми (бигрәк тә кышын). Төркемдәге 50 сыерның һәрберсенә аерым игътибар, аерым мөнәсәбәт кирәк.Бүген сөт саву процессы күбесенчә механикалаштырылган булса да, аңа карап кына сыер савучы эше җиңеләйми. Тирес кыру, авыр-авыр капчыклар күтәреп, ашарга салып йөрү, берничә сәгать бертуктаусыз аягөсте эшләү – хатын-кыз өчен биниһая зур хезмәт! Берәр сыерың тибә торган, икенчесе сөзә торган да булса – монысы бөтенләй аерым очрак. Көн саен шул үзенчәлекле исне иснәп эшләүләре өчен генә дә медаль бирерлек аларга!Моннан тыш, фермасында да бер көтү сыер савып кайткан хатынны өендә дә шул ук эш көтә – күбесенең хуҗалыгында сыерлар бар. Әле ике савым арасындагы өйдәге бер олау эшне санамадым. Ашау пешерү, юу-җыю бер хәл, балаларны уятып, бакчага-мәктәпкә озату, кичен дәресләрен әзерләшү-тикшерү дә бар бит әле. Кая ул сыер савучыга йокы дигәннәре?..

Һәм әлеге һөнәрнең тагын бер зур минусы – алар ел әйләнәсе, бәйрәмсез, ялсыз, шимбә-якшәмбесез – һәр көнне (!) эшли.

*III.Йомгаклау*

Сыер саву – бик җаваплы, авыр эш, җирлекнең авыл хуҗалыгы тармагының уңышы нәкъ менә сыер савучылардан тора, чөнки сөт – авылда төп керем чыганакларының берсе.Әлеге эзләнү эшенең нәтиҗәләре нинди булды соң?

1. Эзләнү барышында без 80-90 елларда һәм бүгенге көндә эшли торган барлык сыер савучылар белән очрашып чыктык, аралаштык. Алар бик теләп безгә үзләренең хатирәләре белән уртаклаштылар. Нәтиҗәдә, мәктәп музее өчен бик бай материал барлыкка килде.
2. 80-90 елларда эшләгән сыер савучылар барысы да алдынгы булганнар, бик күп хөкүмәт бүләкләренә ия булганнар. Алар арасында 4 “Татарстанның атказанган терлекчесе”, 1 Ленин ордены, 3 Октябрь революциясе ордены кавалерлары, Партсъезд, яшьләр фестивале делегатлары бар
3. 60, 80 нче елларда эшләгән сыер савучылар хезмәте белән бүгенге сыер савучыларның эш шартларын чагыштырдык, бүгенге яңа технологияләр эш шартларын бик җиңеләйткән, сыер савучылар физик хезмәт белән шөгыльләнми диярлек. гадәти фермада бу кадәр малны ашату, саву өчен 32 савымчы кирәк булса, биредә бу эшне 5-6 кеше башкара ала. Аз сандагы кеше күләмле хезмәтне башкаргач, хезмәт хаклары да югары.
4. 80-90 нчы елларда фермада барлыгы 95 кеше эшләгән. Ә бүгенге яңа технологияләр чорында, әлбәттә, эшчеләр саны кыскарган. Бүген фермада эшләүчеләр саны 50.Моның алга таба тискәре нәтиҗәсе дә булырга – структур эшсезлек килеп чыгарга мөмкин. Ә бу авылда яшәүчеләрнең кимүенә китерәчәк.
5. Бүген фермада эшләүче сыер савучылар белән үткәрелгән сораштыруларның нәтиҗәсе куанычлы. Алар сыер савучы һөнәренең 10 уңай ягын күрсәтә алдылар. Бу позитив нәтиҗә ясарга мөмкинлек бирә – алга таба да бу һөнәрнең дәрәҗәсе булыр дип өметләнәссе килә.

Бүген сыер савучы һөнәре элеккеге белән чагыштырганда, бик күпкә үзгәрде һәм киләчәктә дә үзгәрәчәк. Якындагы 15-20 елда кеше факторыннан 90-95 процентка китәргә мөмкинлек туачак. Хәзер роботлар белән саву, “карусель” дигән төшенчәләр беркемне гаҗәпләндерми, бу гадәти күренеш. Әлеге хезмәттә ир-атлар да, хатын-кызлар да эшли ала. Чит илләрдә, Европада, әйтик, ир-атлар сыер сава, чөнки бу – авыр хезмәт. Хәзерге вакытта заманча технологияләр республиканың 20-25 процент фермасында гына юк, аларда һаман савым чиләкләре кулланыла. Әмма киләсе 6-7 елда әлеге аппаратлар бетәчәк, барлык фермаларны сөт үткәрү торбалары белән тәэмин ителәчәк. Авылның киләчәге – үзенең язмышын туган төбәге белән бәйләргә теләгән, аны яратучы фидакарь, ватанпарвәр хезмәткәрләр кулында.

*Кулланылган әдәбият*


1. Бикбаев Г.Б. Һәр сыердан дүрт тонна сөт. Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1982
2. Сабитов А.Ф. Знатные люди Кукмора. Казань, ГУП “ИПК “Чувашия”, 2012
3. “Хезмәт даны” газетасы архивы
4. “Социалистик Татарстан” газеталары
5. “Азат хатын” журналлары
6. Сыер савучыларның гаилә архивлары

# ӘШНӘК АВЫЛЫ ТАРИХЫ

*Валиев Айрат Ренатович, ученик 5 класса,*
*Научный руководитель – Хафизова Расима Миннулловна*
*МБОУ «Рыбно-Слободская средняя общеобразовательная школа №2»*
*Рыбно-Слободского муниципального района*

Тарих! Биш кенә хәрефле сүз булса да, үз эченә меңнәрчә-миллионнарча еллар, күпме гасырлар сыйдырган. Гомер итү башланганнан бүгенге көнгә кадәр күпме сулар аккан, күпме буыннар алышынган. Галимнәр һаман да тарихыбызны тикшереп торалар, ләкин ил тарихында байтак нәрсә безнең өчен әлегә сер булып кала бирә.

Борынгы бабаларыбыз бик белеп әйткәннәр: үзебезнең үткәнебезне, килеп чыгышыбызны, тарихыбызны яхшылап белми, өйрәнми торып, без тыныч кына киләчәгебезгә атлап керә алмыйбыз. Тарих бит ул олы диңгез кебек вак-вак тамчылардан җыела, шул "тамчылар" ярдәмендә безнең үткәнебез, бүгенгебез һәм киләчәгебез формалаша. Ләкин кызганыч: барлык фактлар да теркәлеп бара алмый, кайбер вакыйгалар, язылып бармау сәбәпле, вакытлар узу белән онытыла, хәтердән җуела. Шуның нәтиҗәсендә тарихыбызга зыян килә, аның бер чите кителә.

Шуңа күрә мине түбәндәге сораулар борчыды:

-Авылыма нигез салынуның төгәл вакыты кайчан?

- Нигез салучылар кемнәр булган?

- Авыл атамасы каян килеп чыккан?

Укытучым ярдәме белән, әлеге сорауларга җавап табарга теләп, өстәмә чыганаклар эзләдем.

Миндә кызыксыну уянды, фәнни-тикшеренү эше белән шөгыльләнергә уйладым һәм максатым итеп авылымның килеп чыгышы тарихын, топонимикасын өйрәнүне, барлауны алдым.

Максаттан чыгып, үз алдыма түбәндәге бурычларны куйдым:

- Олы Әшнәк авылы тарихының төрле чыганакларда, риваятьләрдә яктыртылуына тукталу; атамаларны өйрәнү;

- туган телгә, туган авылга, туган якка, туган җиргә мәхәббәт тәрбияләү.

Проект эше барышында мин тикшерү, эзләнү, сораштыру һәм нәтиҗә чыгару алымнарын кулландым. Тикшерү эшен башкарганда газета-журнал чыганакларына, фәнни һәм матур әдәбиятка, тарихчыларга, авыл елъязмасына мөрәҗәгать иттем.

Тикшерү объекты булып Балык бистәсе муниципаль районының Олы Әшнәк авылы тора.

Фәнни эшнең тикшерү предметы итеп авыл тарихы һәм топонимикасы алынды.

Эш барышында мин түбәндәге эзләнү-тикшеренү алымнарын кулландым: Куелган максат һәм бурычлардан чыгып, эшемне шундый планда төзедем. Ул кереш, төп һәм йомгаклау өлешләреннән, кулланылган әдәбият исемлегеннән тора. Төп өлешне түбәндәге бүлекләр тәшкил итә:

1. Тарихтан бер сәхифә.
2. Биләр каласы харәбәләре

*1. Тарихтан бер сәхифә*

Авылыбызның исеме ни аңлата, кайчан кушылган, кем кушкан, ни өчен шулай кушкан, атама нинди үзгәрешләр кичергән – барысы да кызык бит, шул ук вакытта күпме сорау, күпме сер! Авылның чал тарихы белән кызыксыну табигый бер хәлдер, бу – авылыңа, төбәгеңә, ватаныңа гамьсез булмау, биредә тамырларыңның тирән береккәнлеге билгеседер.

Балык Бистәсе районында урнашкан “Олы Әшнәк ” авылы Идел буе Болгар дәүләте чорындагы иң борынгы авылларның берсе . ОЛЫ́ ӘШНӘ́К авылы , Татарстан җөмһүрияте, Балык Бистәсе районында. Шәһәр тибындагы Балык Бистәсе посёлогыннан 19 чакырым төньяк-көнбатышта Әшнәк елгасы буенда урнашкан.

XVIII йөздә — IX йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына кергән, авыл халкы игенчелек, терлекчелек, урманчылык, умартачылык, балта эше һәм тегүчелек белән шөгыльләнгән. XX йөз башында Олы Әшнәктә 2 мәчет, 2 тимерчелек алачыгы, 2 тегермән, 3 ярма яргыч, 12 вак-төякләр кибете (лавкалары) эшләгән. Бу елларда авыл җәмәгатенең имана җире 2794,8 дисәтинә тәшкил итә. 1920 нче елга кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Масловка волостенда, 1920 дан ТАССР ның Лаеш кантонында, 1927 нче елның 14 февраленнән — Балык Бистәсе, 1944 нче елның 19 февраленнән — Солтан, 1946 нчы елның 5 апреленнән — Корноухово, 1954 нче елның 19 ноябреннән — Балык Бистәсе, 1963 нче елның 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нче елның 12 гыйнварыннан Балык Бистәсе районына керә. Олы Әшнәк авылы зиратында XIII - XIV йөзләргә карый торган ташъязма истәлекләре (кабер ташлары) саклана.

Академик Г.Ф. Саттаров фикеренчә “Әшнәк” авылы атамасы нигезендә фарсы алынма сүзе яисә этимологиясе нигезендэ удмурт сүзе булырга мөмкин “Ош+няк”, “Ош+нюк” (“Ош” удмуртчадан гидротопономик термин буларак - чишмә, елга).

Халык риваятләренә караганда “Әшнәк” авыл атамасы “Әшнә” – дуслар, иш(эш), әшнәләр(туганнар)” мәгънәсеннән килеп чыккан булуы ихтимал. Авыл картларының риваятләренә караганда Әшнәк авылына нигезне узара туганлашкан Болгар һәм Мари гаиләсе нигез салган дигән вариант та бар.

Авыл җирлегендә иң беренче археологик эзләнүләрне атаклы галим Николай Филипович Калинин (1888-1959) үткәрә.

Ул бу фәнни тикшеренү эшенә сугыш башланганчы керешкән була һәм сугыш беткәч, 1948 нче елны гына дәвам итәргә туры килә. Археологик табылдыклар С. Петербург һәм Мәскәү калаларына җибәрелә.

2014 нче елда археолог, Фәннәр Академиясе тикшеренү институтының өлкән фәнни хезмәткәре Николай Истомин, Олы Әшнәк авылында асфальт юл салу алдыннан, казу эшләре алып барганда Алтын Урда, Болгар чорына караган бик күп кенә тарихи экспонатларга юлыга. Аларның күбесе борынгы Болгар, Биләр шәһәрләрендә табылганнарга тиң була. Галим фикеренчә авылга нигез якынча XIV нче гасыр азагы XV гасыр башларында салынган булырга тиеш. 14 гасырдан алып санаганда 6 гасырдан артык!

1956 нчы елда Олы Әшнәк авылында тарихчы галим-археолог Һарун ага Йосыпов булып китә. Ул зираттагы борынгы кабер ташларына игътибар итә.Йәмән атлы кешенең кызы- Сәвиләнең кабер ташындагы куфи ысулы белән язылган сүзләрнең тулы текстын укый алмаса да, Сәвилә 1320 нче елда күмелгән дигән датаны азсызыклый. Олы Әшнәк зиратында тарихи һәйкәл кабер ташларына кертелгән 7 таш бар. Зираттагы борынгы таш Гарәп графикасы белән язылган кабер ташы.

Әлеге ташлар якынча 700-750 еллар элек куелыну исбатлый. Тарихчы-галимнәр ул вакыттагы бер кеше гомерен уртача 25-27 ел хисабыннан санап эш итә. Сәвиләнең, аның әтисе Йәмәннең һәм бабасы Мөхәммәт-хуҗаның гомерен нәкъ шушуы кысаларга карап тапкырласак, Олы Әшнәкнең ким дигәндә 1240 елда нигез салынган булуы ачыклана”.

Ә бәлки тагы да иртәрәк? Ник дигәндә, беренчедән, кешенең гомере 25 елга гына тигез түгел. Икенчедән, авыл урнашкан урынннан 7-6 чакырым ераклыкта гына Чулман елгасы янында мәшһүр Кашан каласы булган (аны монголлар җимергәнлеге билгеле). Монгол яулары бу шәһәрне җимергәннән соң, Җүчи олысы чорында Кашан шәһәрен берничә чакырым ераклыкта көнбатыштарак урнашкан Шуран авылы янында торгызалар. Кызганычка каршы, 1391 нче елда Аксак Тимер тарафыннан бу шәһәр дә җимерелә.

Кашан шәһәре – Болгар ханлыгындагы Кашан әмирлегенең башкаласы булган. Бу әмирлектә Болгарлар белән бергәлектәторган (союзник булган) кабиләләр яшәгән. Әмирлекләр бар икән, димәк авыллар да бар дигән сүз. Шулар арасында “Олы Әшнәк” (Әшнәк) авылы булуы да бик ихтимал.

Болгар ханлыгында шәһәрләр янында дистәгә якын чакырым ераклыкта авыл-крепостьләр төзелгәнлеге мәгълүм. Алар дошман яуларыннан шәһәрне саклау, дошман килү турында тиз арада хәбәр итү ролен үтәгәннәр.Гадәттә калкулы, таулы урынга биек башнялар

салына торган булган.Бу башнялар шәһәргә кадәр бер-берсенә күз күремендә салынганнар. Дошман яуы күренүгә, башня өстендә учак ягыла, санаулы минутлар эчендә дошман килүе билгеле була.

Шулай ук мондый авыллар товар алышу, сәүдә итү ролен дә үтәгәннәр.

Олы Әшнәк авылының төньяк көнбатышына үтә торган юлны “Пулат юлы” (“Булат” сүзеннән килеп чыккан) дип атыйлар. Билгеле булганча, көнчыгыш Европада яхшы сыйфатлы тимердән эшләнгән сугыш кораллары (кылыч , сөңге, калкан һ.б.) ясау үзәге булып нәкъ менә Болгарның Кашан шәһәре торган. Монгол яулары тарафыннан җимерелгән, ә менә яңадан торгызылган Кашанда сугыш кораллары эшләнгәнлеге билгеле түгел. Димәк, Пулат (булат) юлы атамасының Болгар чорына каравы бәхәссез. Бу мисал да Олы Әшнәк авылына 1239 еллар тирәсендә алдан нигез салынган дип уйларга мөмкинлек бирә.Шулай ук, авыл халкында саклана торган риваять тә бу фикерне раслый сыман. Бу риваятьнең кыскача эчтәлеге түбәндәгечә :

“Авылның көнчыгышында (хәзерге “Кәрәкә күле” янында) калкулык крепость (ныгытма) ролен үтәгән. Монгол яулары һөҗүме башланганнан соң, яуларда җиңелгән күп кенә гаскәри болгарилар шушы ныгытмага киләләр. Аның хуҗабикәсе сылу һәм бик батыр кыз Сөмбеләбикә булган имеш. Монгол яуларына аяусыз көрәшне Сөмбеләбикә җитәкләгән. Бу сугышта ул үзе генә дә дистәләрчә Монгол яу гаскәриләрен юк иткән.Сөмбеләбикә үзе һәм аның батыр сугышчылары туган җирләрен саклап вафат булалар. Сөмбеләбикәне дошманнар үз кулларына төшерә алмыйлар, ул турыдан – туры оҗмахка эләгә, имеш. Шуннан соң җир тетри, калкулык асты иңә, аннан шифалы зәм-зәм суына тиң чишмә бәреп чыгып, күл хасил була. Ул күл – “Кәрәкә күле” дип атала.Күп кенә яралы сугышчылар шушы күлгә кереп яталар, аз гына вакыт эчендә аларның яралары төзәлә, җаннары сихәтләнә.Алар үзләренең вафат булган иптәшләрен авыл урнашкан урыннан көнбатыш якка, Әшнәк елгасы буена җирлиләр.Бу урынны авыл кешеләре хәзердә “Изгеләр зираты” дип йөртәләр. Археологлар тарафыннан бу урыннарның тикшерелгәне юк.

Хәзерге вакытта да “Кәрәкә” күленең ләме төрле тән авыруларын дәвалый дигән фараз яши. Кәрәкә күленә Татарстаннан гына түгел Рәсәйнең төрле төбәкләренннән җәйге эссе көннәрдә дәва табу, ял итү өчен кешеләр килгәннәр. Ләкин,кызганычка каршы, шушы Кәрәкә күле буендагы калкулык та археологлар тарафыннан тикшерелмәгән. Әгәрдә бу эш үткәрелгән булса, авылның барлыкка килү вакыты да шулай ук, төгәлерәк ачыкланган булыр иде.

*Биләр каласы харәбәләре*

Исән калган халыкның бер өлеше җимерек шәһәрдән качып китәргә мәҗбүр була. Бату гаскәрләре урыс кенәзлекләрен һәм Европаны тезләндерү өчен көнбатышка киткәч, Җик-мәргән һәм Баян-батыр җитәкчелегендәге Болгарлар 1238 елда үз илләрен кабат торгызу өчен милли-азатлык көрәшенә күтәрелеп чыгалар. Шул елларда, Биләр каласы җимерелгәч, шәһәр халкының бер өлеше (күбесенчә хатын-кызлар һәм балалар) Каманың уң ягына күчеп, шул рәттән “Әшнәк” авылына нигез салганнар дигән фикер дә бар. Казан ханлыгы чорында гына “Әшнәк” атамасына “Олы” сүзе өстәлә.

Алексеевск районында “Әшнәк” атамалы авылның булуы да бу бергәлекне исбатлаучы мисал булып тора. Биләр төбәге “Әшнәк” авылы белән элемтәне түбәндәге мисаллар да раслый: Олы Әшнәк авылының берничә ир-аты чиратлап Каманың аръягы, хәзерге Алексеевск районында калган Болын-хуҗа ханның каберен саклый торган булганнар. Казан белән Сафаргәрәй хан идарә иткән вакытта (1524-1549). Болын-хуҗа кабере өстенә ташпулат та төзеп куялар. Хан фәрманы буенча Барямгос, Тюлялчеин Шахкамалов (урыс документларынан шулай барып кергән) һәм аларның 6 иптәшенә Биләр харәбәләреннән 2-3 чакырым ераклыкта Кече Чирмешән елгасы буенда махсус җир дә бүлеп бирелә. Ләкин, 1552 нче елда Явыз Иван Казан каласын яулап алганнан соң, Болын-хуҗа ташпулатын һәм аның сакчыларын юкка чыгаралар.

Авылдан ярты чакырым ераклыкта борынгы зиратта 1339-1347 нче елларда куелган һәм куфи ысулы белән язылган Олы Әшнәктәге кебек 5 кабер ташы сакланган. Мишәрләр әлеге

урынны “мазарка” дип йөртәләр. Алексеевск районындагы “Әшнәк” белән Балык Бистәсе җирлегендәге “Олы Әшнәк” авылын менә шундый борынгы җепләр бәйли. Гаҗәбе шул: Олы Әшнәктә яшәп калган туганнары да читкә куылган ташпулат сакчыларын озак еллар буена онытмыйлар. Олы Әшнәктән Морза Мәмәт Кәмлә 1677-1678 нче елларда патша Алексей Михайлович исеменә берничә тапкыр үтенеч хаты язып, Биләр ягыннан читкә куылган Ишбулат һәм аның энесе өчен ясак түләргә рөхсәт сорап мөрәҗәгать итә.

Хәзерге Әшнәк авылы урнашкан урынның көньяк-көнчыгышында иксез-чиксез, Чулман елгасына кадәр җиткән, кораблар төзүгә яраклы имәннәр үскән. Элек шушы урманлыклар уртасынныан зур гына инеш аккан. Бу инешне соңыннан ”Лашман елгасы” дип атый башлаганнар. Хәзер дә авылда “ Лашман юлы” “ Лашман чокыры” “Лашман төбәге” дигән атамалар яшәп килә. Эчтәлегенә килгән вакытта, ул атама урман кисүчеләр, урман әзерләүчеләр дигәнне аңлата. Авыл кешеләре нигездә дәүләт крестьяннары - “лашманчылар” булып та эшләгәннәр.

“Лашманчылар”- Петр I заманында ясала башлаган сугыш көймәләре өчен, агач кисүче крәстианнар. Лашман сүзе немецчәдән- “Laschmann” – «кисүче кеше» дигән сүздән алынган. 1721 елда махсус штаб ачыла һәм лашман хезмәтенә башта 170 мең, соңрак 120 мең кеше билгеләнә. Шул вакытлардан башлап, сугыш көймәләре ясау тукталганчы һәм лашман хезмәте беткәнче, халыкның имән кискәне исбатланса, ул яман җәзага тартыла һәм аңа үлем куркынычы яный.Лашман хезмәтенә язылган кеше 15 яшьтән 60 яшькә кадәр хезмәт иткән. Байлар яллап эшләткәннәр.. Ул үлгәч, аларны, башка халыктан алган төсле, салым түләтеп, башка төрле эшләр эшләтеп, солдатка да ала башлаганнар. Хәтта хөкүмәт аларның иткән хезмәтләре тәкабеленә мунчадан алына торган бер сум салымны да алудан туктамаган. 1859 елда «Лашман» хезмәтен, атлы һәм җәяүлесен дә бетерәләр.

1719 елда Казанда, корабларга җилкәннәр эшләү максатында, мануфактуралар барлыкка килә. Бу мануфактураларга һәм адмиралтействоларга авылның шактый кешеләре даими эшкә көчләп күчерелгәннәр. Картлар әйтүенчә, аерым алганда монда 20 еллар элек, 90 яшьләрендә мәрхүм булган Гайнетдинов Гайнетдин истәлекләренннән күренгәнчә, Казанда авылдан чыккан күп кенә кешеләр байтак заманнардан бирле яшәп килгән туганлык җепләренең өзелмәве шул турыда сөйли.

Шул елларда дәүләт, чәчүлек җирләре белән беррәттән, урманннардан чистартып, элек авылга караган җирләрне Макашин, Завалишин кебек бай кешеләргә бирә. 16 нчы гасырларда Мәскәүдән ерак булмаган “Корноухово” дигән авылдан Мертвага дигән кеше күчеп килеп “Ырга һәм “Әшнәк” елгалары кушылган урында “Корноухово” дигән авылга нигез сала. Бу җирләр бик уңдырышлы була, су буйларындагы болыннарда терлек йөртерлек киң болыннар җәелгән.

Фәнни-тикшеренү эше белән шөгыльләнеп, мин түбәндәгеләрне ачыкладым:

•кечкенә генә туган авылым Әшнәк зур тарихка ия;

• авылым тарихы төрле чыганакларда , чагылыш тапкан; фәнни эш белән шөгыльләнү телебезгә, гореф-гадәтләребезгә, туган җиребезгә булган мәхәббәт хисләрен көчәйтте, милли мирасыбызны өйрәнүгә этәргеч ясады.

Нәтиҗәдә, миндә алга таба авылым тарихын киңрәк өйрәнү теләге туды.

*Файдаланылган әдәбият*

1.Алишев С.Х. “Татары Среднего Поволжья в пугачёвском восстании”. Казань, 1975, стр.178

2.Гариф Нурулла. “Тарихи сәхифәләр ачылганда”. –Казан ,2008, 26-27 нче битләр.

3.Гыйльмуллина Л. “И, газиз туган ягым!” Казан, 2008, 7, 58-60 нчы битләр.

4. Насыров Р. «Сельское расселение в Западном Закамье», Казань,1986, стр.98.

5.Список селений Казанской губернии. – Казань, 1908, стр.62.

6. Татар әдәбияты тарихы. Казан, 1973, 56, 83, 122, 259 нчы битләр.

7.Трофимова М.И. «Рыбная Слобода. Живые голоса», Казань, 2006, стр.21.

# ЯКТАШЫМ – ШӘЙХИ МАННУР

*Ганиуллин Илхам  Ринатович, ученик 9 класса*
*Научный руководитель – Саляхова Лейля Шамиловна*
*МБОУ «Тавельская СОШ»*
*Мамадышского муниципального района РТ*

Туган җир ул кеше күңеленә
Ана сөте белән салына...
*Саҗидә Сөләйманова*

Туган җир. Туган туфрак. Туган төбәк. Ул һәркем йөрәгендә яши һәм вакытлар үтү белән әлеге төшенчә тагын да зур мәгънәгә ия була. Туган якның бай тарихы һәм мәдәнияте, табигате – болар барысы да кече яшьтән үк тормышыбызның бер кисәгенә әверелә. Шуңа күрә әдәби туган як әдипләрен барлау — мәктәптә укудан тыш әһәмиятле чараларның берсе. Ул безнең туган ягыбызның тиешенчә яктыртылмаган мәсьәләләрен тирәнрәк ачыклауга ярдәм итә, әдәбият белән кызыксынуыбызны үстерә, әдәби карашны киңәйтә, китап белән мөстәкыйль эшләү күнекмәләрен баета, фәнни-тикшеренү, эзләнү эшенә тарта.

Безнең данлы Мамадыш ягы язучылары үзе туган, үскән, яшәгән һәм әсәрләрен иҗат иткән урыннан аерылгысыз, чөнки әдип иҗаты өчен азыкны үзенә яхшы таныш булган җирлектән ала. Аларны сокландырган туган табигать, аның кешеләре, тормыш-көнкүреш йолалары әсәрләренә күчәләр, тылсымлы сүз остасының каләм көче белән гади тормыш картиналарына әвереләләр. Язучыларыбыз үзләре күргән вакыйгаларны, күренешләрне тулырак, җанлырак яктыртып, кызыклы әсәрләр язалар. Шуның өчен дә районыбызда алар белән очрашулар еш булып тора, әсәрләрен дә яратып укыйбыз.

Әдәби туган якны өйрәнү безгә ни өчен кирәк? дигән сорауга туган җиргә мәхәббәт нигезендә патриотизм һәм милли горурлык тойгысын тәрбияләү өчен кирәк дигән җавап бирер идем мин. Туган җиргә бәйләнгәнлек Ватанга булган мәхәббәт тойгысы белән аһәңдәш бит!

Төп максатым: туган ягымның иҗат өлкәсенә зур өлеш керткән бөек шәхесләрен белү, аларны барлау. Тикшеренүләрем нәтиҗәсендә шуларны белдем: Мамадыш җирлегендә туып-үскән шагыйрьләр һәм күренекле кешеләр байтак. Мәсәлән, Иске Комазан авылында туып-үскән шагыйрь, атказанган мәдәният хезмәткәре Вахит Галиев; Кече Кирмән авылыннан чыккан шәхесләр - язучы Ринат Мөхәммәдиев, шагыйрь-прозаик Рафаил Газизов; Кече Сөннән – композиторлар - Заһидулла, Фәрит һәм Мирсәет Яруллиннар; Түбән Ушмы шагыйре Зиннур Мансуров; Ак Чишмә авылы шагыйре Әхмәт Әдил (Гаязов); Яңа Комазан авылының (әле күпләр язучы буларак та белмәгән) язучысы Рәим Гобәев; Тулбай авылыннан чыккан зур шәхес Шәйхи Маннур – болар барысы да безнең татар әдәбиятын һәм мәдәниятен үстерү өчен үзләреннән зур өлеш керткән зур хөрмәткә ия, исемнәре халык күңелендә мәңге яшәячәк шәхесләребез.

Без узган уку елында мәктәп күләмендә үткәрелгән чарада якташ шагыйребез - сынмас рух көченә ия булган - Шәйхи Маннур иҗаты белән таныштык. Язмышның зур сынауларына дучар булган язучының  “Муса” романы безнең өчен зур үрнәк,  батырлык символы булып тора. Шушы әсәре  генә дә аның иҗатының югары дәрәҗәдә булуын күрсәтә һәм мин бу якташым турында күбрәк белергә теләп, фәнни-эзләнү эше язарга уйладым. Без кечкенә классларда укыганда ук аның шигырьләрен укып, ятлап килдек. Укытучыларыбыз шигырьләргә никадәр тирән хис, акыллы фикер һәм зур мәгънә салынганлыгын төшендерергә тырышты. Чыннан да,  шигырьләрендә дә,  бу тормышта биеккә ашкынган кешеләргә туган җирне онытмаска куша, күңелдәге хисләрне бөтен нечкәлеге белән ачып сала ала торган кече җанлы шагыйрь икән ул.

Ләкин аның турында нәрсә беләбез соң без? Язучылар ни өчен шулай нечкә күңелле булалар икән? Мин дә туган ягымны Шәйхи ага кебек ярата алырмынмы? Нинди эшләр башкарган? Нинди үрләр яулаган?  Минем дә туган төбәгем үсешенә өлешем керерме? Эшемне язу барышында шушы һәм тагын  бик күп сорауларга җавап табарга тырыштым.

*Төп өлеш.* Тормыш юлына күзәтү

Татар әдәбиятының күренекле вәкилләренең берсе, шагыйрь, прозаик, тәрҗемәче Шәйхи Маннур (Шәйхелислам Фәрхулла улы Маннуров) – мәдәниятебез һәм җәмгыятебез тормышында якты эз калдырган олуг шәхес.

Ул 1905нче елның 15нче гыйнварында элекке Казан губернасы Мамадыш өязе (хәзер Татарстанның Мамадыш районы) Тулбай авылында ярлы крестьян гаиләсендә туа. Башлангыч белемне туган авылында һәм күрше авылдагы мәдрәсәдә ала. Аннары күрше Шәмәк авылында ачылган мәктәптә һәм Мамадыш шәһәрендәге педагогия курсларында укый. 1921нче елда аның әтисе гаиләсе белән Кузбасстагы Анжерка-Судженка шахталарына күчеп китә. Шунда Ш. Маннурның хезмәт юлы башлана. Ул 1923 нче елда Свердловскидагы бер еллык совет-партия мәктәбендә укый, биредә чынлап торып әдәби иҗат эшенә керешә. Урал төбәге татарлары өчен чыгарылган газета-журнал битләрендә, соңга таба Казан һәм Мәскәү татар көндәлек матбугатында аның күп кенә шигырьләре һәм әдәби язмалары дөнья күрә.

1924 нче елдан Ш. Маннур өч елга якын Себернең төрле төбәкләрендә яши һәм эшли. 1927-1929 нчы елларда армия сафларында хезмәт итә. Армиядән кайткач, Донбасс якларына китеп, металлургия заводында - эшче-прокатчы, шахтерлар мәктәбендә - укытучы-ликбезчы һәм ДнепроГЭС төзелешендә бетончы хезмәтендә була. Бу елларда Ш.Маннурның иҗат эшчәнлеге аеруча активлаша. Ул «Колчеданлы таулар өстендә» (1929), «Чуен ташкыннар» (1930), «Бетончылар җыры» (1932) исемле беренче поэмаларын һәм күп санлы лирик шигырьләрен яза. Аның бер-бер артлы шигырь җыентыклары басылып чыга. Мәскәүдә, «Эшче» газетасы редакциясендә эшләп алгач, Ш. Маннур Казанга килә һәм 1933-1937нче елларда педагогия институтында укый. 1934нче елда аның атаклы «Гайҗан бабай» һәм тагын бер елдан «Меңнән бер кичә» поэмалары языла. Бөек Ватан сугышы башлангач, шагыйрь үзе теләп фронтка китә, хәрби газеталарда эшләп, күп санлы хәбәрләр, очерклар, шигырьләр бастыра. Сугыштан соң, 1946-1948нче елларда Ш. Маннур Казанда Муса Җәлил исемендәге татар дәүләт опера һәм балет театрының әдәби бүлек мөдире булып эшли, ә 1949 нчы елдан профессиональ язучылык хезмәтенә күчә.

1960-70 нче еллар әдәби хәрәкәтендә Ш. Маннур прозаик буларак катнаша. Ул иҗат иткән проза әсәрләре арасында иң күренеклесе - «Муса» романы (1959-1964). «Агымсуларга карап» исемле автобиографик (1970-1973), «Чын сөю бармы?» (1974-1976) исемле лирик повестьлары белән Ш. Маннур үзен талантлы прозаик, үзенчәлекле хикәяләү стиленә ия булган каләм остасы итеп таныта. Ш. Маннурның әдәби мирасы зур һәм күпкырлы. Үзе исән чагында аның дүрт дистәгә якын китабы дөнья күрә. Алар арасында махсус балаларга адресланганнары да бар. Ул шулай ук әдәби тәнкыйть, публицистика, очерк һәм әдәби тәрҗемә жанрларында да нәтиҗәле эшли.

Ш. Маннур 1980 нче елның 10 нчы июнендә Казанда вафат була һәм үзенең язма васыяте буенча туган авылы Тулбай авылы зиратына җирләнә. Ш. Маннур 1957 нче елда туган авылында үз акчасына китапханә салдыра һәм 1980 нче елда китапханәгә Шәйхи Маннур исеме бирелә. 1995 нче елда аңа Татарстан берләштерелгән дәүләт музееның филиалы статусы бирелә һәм музей-китапханә исемен йөртә башлый. 1981 нче елдан бирле һәр елның 15нче гыйнварында, язучының туган көнендә, туган авылында Шәйхи Маннур исемендәге премия бирелеп килә.

Татарстанның халык шагыйре Илдар Юзеев истәлекләреннән.

1971 нче елның августында ул мине, Татарстан Язучылар берлеге коридорында туктатты да: ”Менә шуны ал әле”, - дип кулга тоттырды. Үзе берни дә анлатмыйча, китеп тә барды. Конвертның тышына : ”Сонгы сәгать суккач укырсың...” дип язылган иде. Мин моның васыять икәнен анладым. Шәйхи аганын шифаханәдә вафат булганын ишеткәч, ачып укыдым. Анда мондый сузләр язылган иде:

“Хөрмәтле Гомәр ага Бәширов, хөрмәтле энекәшләрем Илдар Юзеев, Шәүкәт Галиев, Хисам Камалов!

Күп дусларым арасында Сез минем иң якын күргән дусларым. Шуңа күрә мин сезнең өскә бик авыр эш йөкләргә батырчылык итәм. Сез инде мине гафу итегез.

Бер дә көтмим...
Ләкин ул килер,
Суык кулын бирер,
Әйдә, диер,
Кузләреңне бәйлә, диер,
Җитәклим дә алып китим,
Яңа фатирыңа илтим...

1. Менә шул көнне инде сез минем бу хатны ачып укыгыз да гәүдәмне Тулбайга алып китегез, шау-шулы мөрасимнәр булмаса да ярый. Анда ике урын булыр. Берсе зиратта, анам кабере янында. Икенчесе – китапханә бакчасында. Кайсын сайлау сезнең һәм авылдашларның ихтыярында.

2. Кабер өстенә таш утыртып, чардуган корылса һәм берничә сүз яздырсагыз яхшы булыр иде.

Синең бар җирең сөекле
И Тулбаем – моң илем,
Бул бәхетле, бул ирекле –
Бар теләгем шул минем,-

дигән юллар бар. Ләкин күнел барын да әйтеп бирә ала микән? Бәлки, сез, шагыйрь, дусларым, үзегез матуррак сүзләр табарсыз?

3. Алып китү һәм күмү вакытында тотыла торган барлык чыгымнарны каплау өчен билгеләнгән биш мең сум акчам бар. Моны алу юллары сезгә мәгълүмдер.

4. Өйдәге барлык китапларны Тулбай китапханәсенә тапшырыгыз... Гомумән, Тулбайдагы ул китапханәне сүндермичә яшәтәсе иде. Шундый ерак һәм бәләкәй авылда мәдәни-әдәби бер учакның әзме-күпме якты сибеп торуы начар булмас иде кебек...”

Шәйхи Маннур узенен туган авылын бик тә яраткан. Юкка гына ул узен туган як зиратына күмүләрен сорамаган. Хәтта ул узенен “Агымсуларга карап” дигән әсәрендә дә бик еш Тулбай якларын искә ала...

“Туган авыл...Читтән караганда чокырда утырган Тулбай, ”Тулы бай” дигән мәгънәдә булса, исеме бер дә җисеменә туры килми торган ярлы авыл, шулай да Туган авыл! Мин юктагы ел ярым эчендә бер дә үзгәрмәгән ул: шул ук “сәҗдә”гә киткән мескен өйләр, кыйшык-тишек дигәндәй абзар-кура, буйдан-буйга салам түбә. Җитмәсә, ул өйләрнең әйләнә-тирәсенә салам-тирестән “диңгез” салганнар хәзер, кышкы суыктан салам тун! Бу “киеме” тагын да боеграк күрсәтә ул өйләрне.

Чит җирләрдә “дөнья күреп “кайткач, туып үскән авыл бик тә күнелсез күренде, шактый вакыт ияләнә алмый йөдәп беттем.”

Бөек шагыйрнең безнең арабыздан киткәненә бик күп вакыт узса да, без аны онытмадык һәм онытачак түгелбез.

Беренче сыйныфта ук без аның шигырьләре белән танышабыз һәм гомернең ахырына тикле шул әсәрләргә таянып яшибез.

1.2.Туган ягы кирәк кешегә

Татар әдәбиятында Ш.Маннурның иҗаты зур урын тота. Аның кабатланмас көчле рухта язылган әсәрләре халкыбыз тарафыннан яратылып укыла килде. Хәзерге көндә дә саекмас моң чыганагы булып хезмәт итә.

Шәйхи Маннур йөргән юллар картага төшерелсә, Рәсәй картасы шактый куе сызыклар белән челтәрләнер иде. Шагыйрь күпне күрә, күпне ишетә. Күпне күрүнең бер сере шунда, ул үзе шул яңа тормыш төзергә олы юлга чыккан хезмәт кешеләре белән бер сафта көрәшче буларак атлый.

Шау-шу да, мин, дан да эзләмәдем
Тик вөҗданым кушкан бу эшне
Үтәдем мин - җаным җәлләмәдем,
Үтәдем мин - ничек тиешле,

- дип язды шагыйрь үзе. Кузбасс, Донбасс шахталарында ул «күкрәкләргә газлы төтен йотып, төтенсез саф дөнья ясаучыларның берсе үзе була, бетонщик булып үзе чал Днепрны йөгәнләүдә катнаша, металлургия заводларында эшли. «Елмаюлы кояш турында» (1929) исемле шигырендә ул рабфак бетереп кайткан кызның «авылга кояш китерүе» турында язган шикелле, үзе дә Себер, тайга урманнары арасында адашкан авылларда «кояшны күрергә» өйрәтә.

Ул кайларда гына йөрсә дә, (Свердловск, Тобол, Новосибирск, Донбасс, Днепрострой, Мәскәү, Казан ... һәм башка бик күп җирләр) туганягын онытмый. Бигрәк тә туган авылы турында сөйләгәндә, туган җиргә булган хөрмәте һәм ярату хисе гаять тирән булуы күренә.

Юк!
Күпме генә җирләр йөрсәм дә,
Истә йөртәм һаман мин аны,
Нинди генә матур төш күрсәм дә,
Күрәмен мин туган Тулбайны:
Агартса да чәчне картлык, кайгы,
Мин һаман да Тулбай малае.

“Безнең авыл егете” шигырендә йөрәге түрендә - туган авылы – Тулбае булганлыгына басым ясый. Һәрвакыт ярдәмгә килергә ашкынып торучы күршеләре, ап-ак чәчле әбиләре, бакыр куллы тимер агайлары, үзе югында туган һәм инде үсеп буй җиткергән шаян балалары – болар барысы бергә җанына-тәненә иң якыны ди.

Гизсәм дә мин илнең бик күп ягын,
Сырласа да еллар маңгайны,
Мин һаман да Тулбай малае!

Ничә яшьтә булуына карамастан, һаман үзен шул кечкенә генә авыл малае дип хис итә. Һаваланмый, борынын югары чөйми генә, гади булып кала бирә. Үзен Тулбай малае дип атый.

Армия сафларында туган илне фашистлардан саклап дошманның оясына кадәр булган озын авыр юл үтә.

Башкалар җилкәсе артына качып калуны кешелеге, җаны күтәрмәгән. Ул иңенә Җәлилләр, Кутуйлар йөген салып киткән. Тәкъдир аңа каләмдәшләренә караганда миһербанлырак итеп елмайса да, канлы сугышның башыннан ахырынача фронт гәзитләрендә эшләгән, дистәләгән тапкыр үлем белән йөзгә-йөз очрашкан, рус баһадирлары белән рәттән татар сугышчыларының каһарманлыгын да тарихларга керткән.

Шәйхи ага – Муса Җәлилне әле 30 нчы еллар уртасыннан, Мәскәүдә чагында ук күреп белгән кеше. Гәзитләрдә бергә эшләгәннәр, Казанда чагында, бергәләшеп, “Васильево” санаториенда ял иткәннәр, әдәби утырыш яки җыелышларда, бәхәсләшә-бәхәсләшә, уртак тел тапканнар. Шәйхи ага өчен Муса газиз, якын булган. Бөек Ватан сугышыннан соң Җәлил өстенә түгелгән яманатларны да, аның гаиләсе кичкән михнәтләрне дә үз йөрәге аша үткәргәндер. Әнә шул яманатларны тизрәк кырып төшерү, газиз каләмдәшен һәм чордашын милләт тарихына алтын җепләр белән чигү өчен 1959 елда ук “Муса” дигән тарихи романын язуга алынган бит.

Шушы романдагы Муса Җәлил образы кебек үк ул үзе дә батыр, курку белмәс кеше. Әгәр үзең куркак булсаң, шундый зур батырлык үрнәге турында язып булыр идемени соң? Без - яшь буынны - тәрбияләүдә М.Җәлил шикелле шәхесләр барлыгын күрсәтә ала торган шундый күләмле, бөек әсәр язуга алыну үзе зур каһарманлык дип атар идем мин.

Гап-гади Тулбай егете булган Шәйхи ага, татар икенче сортлы халык хәлендә изелгән һәм хөкүмәт аның мәктәпләрен япкан, телен тартып алырга маташкан чираттагы “юкка чыгару” заманында да газиз милләтенең кайнар каны һәм терәге булып, шүрләмичә, күкрәп яши алган.

Татарның әдәби һәм мәдәни дөньясын Шәйхи аганы искә алу бәйрәмнәре уятып җибәрә күк. Мамадыш районы җитәкчеләре, мөгаллимнәр, китапханәчеләр, сәнгать әһелләре һәм балалар һәр ел саен район үзәгендәге Шәйхи Маннур һәйкәле янында шигъри митинг һәм Тулбай авылында тантаналы кичә үткәрә. Инде 36 ел, Шәйхи ага исемендәге бүләккә лаек

булган дистәләгән әдипләрнең исемнәре хәтерләрдә яңармыйча калмый. Шәйхи ага һәр ел саен арабызга кайткан кебек була.

Авылларыбыз бетә, эшче куллар калмый, дип зарланырга яратучы җитәкчеләр өчен Шәйхи аганы тудырган һәм аның рухи мирасы саклаган Тулбай авылы үрнәк була ала.

Ш. Маннур - бәхетле һәм ирекле ил төзү хыялы белән янып иҗат эшеннән туктамаган. Үзеннән соң килгән ничәмә-ничә буыннарга хезмәт итәрлек күркәм музей-китапханә, өендә булган китапларын васыять итеп, бай мирас калдырган. Үз төбәгемнең шундый кешеләре булганга горурланмый мөмкин түгел!

*Йомгак*

Үз туган ягыбыз мәдәнияте һәм әдәбияты үсешенә үзләреннән зур өлеш керткән кешеләр бар. Алар арасында Ш.Маннур исеме безнең өчен иң якыны һәм иң зур дан-шөһрәткә лаек кеше буларак билгеле. Үз башыннан кеше түзә алмас авырлыклар аша узарга туры килеп, яшьли туган авылын ташлап китеп, чит җирләрдә гомер итәргә туры килсә дә, туган җирен онытмыйча, аның турында күп кенә әсәрләр яза, алай гына да түгел, туган авылын иң кадерле истәлек итеп йөрәк түрендә саклый. Моны без үләр алдыннан аның язып калдырган васыяте аша да бик ачык күрәбез: - “...гәүдәмне Тулбайга алып китегез, шау-шулы мәрасимнәр булмаса да ярый. Анда ике урын булыр. Берсе зиратта, анам кабере янында. Икенчесе – китапханә бакчасында. Кайсын сайлау сезнең һәм авылдашларның ихтыярында... Өйдәге барлык китапларны Тулбай китапханәсенә тапшырыгыз... Гомумән, Тулбайдагы ул китапханәне сүндермичә яшәтәсе иде. Шундый ерак һәм бәләкәй авылда мәдәни-әдәби бер учакның әзме-күпме якты сибеп торуы начар булмас иде кебек...” – дип яза ул үзенең иптәшләренә язган хатында.

Димәк, ул башка бик күп язучылар кебек үк, туган җиреннән аерылып яшәсә дә, аны гомере буена сагынып, кайтасы килеп яши, аны ничек тә яхшырту, үстерү, бәхетле һәм ирекле итү, аның данын еракларга таныту турында хыяллана.

Синең бар җирең сөекле,  
И Тулбаем – моң илем,  
Бул бәхетле, бул ирекле –  
Бар теләгем шул минем.

Ләкин күп еллардан соң әйләнеп кайтып, туган авылының шул ук җирлектә, шул ук ярлылыкта көнне-көнгә ялгап тилмереп яшәвен күрә. Һәм чын-чынлап үзенең туган авылының һаман да искечә, бер дә яңара алмаганлыгын күреп борчыла. Үзләре тормыш авырлыгыннан качып киткән авыл, алар кайтканчы, ничек итеп тиз арада яңарып матурлансын соң инде? Авылны бит аның кешеләре яшәтә. Ә уңган-булган кешеләре кимегән саен, авыл да боега шул.

Туган ягыбызның кабатланмас бөек шәхесе булуын аның иҗат җимешләре - шигырьләре раслый. Без аларны укып, бу әдипнең нәрсә турында уйлаганын да, нәрсә дип хыялланганын да күрә алабыз.

Шәйхи ага Маннур мисалында күпләргә туган җирне ничек олыларга кирәклегенә үрнәк алырлык. Мондый фидакарь җанлы кешеләр гасырга бер генә була торгандыр шул. Безгә алардан бик күп нәрсәләргә өйрәнәсе әле.

Район үзәгендә аның хөрмәтенә куелган һәйкәл күпләрне үзенә җәлеп итә торгандыр. Бу үзе үк күп нәрсәне сөйли, димәк аның эшен күргәннәр һәм дөрес итеп бәяли белгәннәр. Моның өчен зур рәхмәт аларга!

Туган авылы – Тулбайда музей-китапханә эшли. Хәзерге көндә дә, анда Шәйхи ага сулышы сизелә. Менә икенче бүлмәдә генә эшләп утырадыр сыман тоела. Һәр почмагы аның нинди кеше булуы, нәрсә белән янып яшәве турында сөйли. Китапханәнең барлыкка килүендә олуг әдип - Ш. Маннур үзе сәбәпче булса, аның бүгенге көндә шундый төзек, матур булып гөрләп эшләвендә авылдашлары, китапханә хезмәткәрләре һәм аның туганнарының өлеше зур. Без аларга зур хөрмәт белән баш иярга тиешбез. Әгәр дә, алар бу эшне дәвам итмәсә, безнең районыбыздан, туган ягын шулкадәр яратучы, аның данын ерак җирләргә танытырга теләүче шундый шәхес чыкканлыгын берәү дә белмәс иде.

Мин дә, үз чиратымда, туган төбәгем шәхесләре белән горурланам, аларга һәрвакыт хөрмәт булсын дип телим! Киләчәктә төбәк язучылары белән очрашып, аларның үзләрен күреп аралашырга мөмкинчелекләр артса, мин бик шат булыр идем. Чөнки үзебезнең якташ язучыларны белү, алар йөргән сукмаклардан йөрү һәм аларның эшен күрә алу - ул үзе зур бәхет!

*Файдаланган әдәбият исемлеге*


1. Мамадыш шәһәрендә басылып чыгучы ”Нократ” газетасы.
2. Музей-китапханәсендәге видео-материаллар.
3. «Татарский энциклопедический словарь» Казань, Институт Татарской энциклопедии АН РТ, 1998.
4. «Татарская энциклопедия» Казань, Институт Татарской энциклопедии АН РТ, 2002-14.
5. Ф. Ф. Исламов, “Әдәбият дәресләрендә туган якны өйрәнү материалларыннан файдалану”, Казан Татарстан китап нәшрияты, 1983.
6. Шагыйрь һәм прозаик Ш.Маннурның тууына 100 ел тулуга багышланган методик-библиографик ярдәмлек.
7. Ш. Маннур “Агымсуларга карап” автобиографик повесте, Казан, Тат.кит.нәшр, 1974.
8. Ш. Маннур “Муса” романы, Казан, Тат.кит.нәшр,1968.


## ТАУ БАШЫНА САЛЫНГАНДЫР БЕЗНЕҢ АВЫЛ


*Гарипова Муслима Мөдарисовна, ученица 5 класса*
*Научный руководитель – Гайфуллина Гульсина Махмутовна*
*МБОУ “Коморгузинская СОШ имени Шигабутдина Марджани”*
*Атнинского муниципального района РТ*


Бу дөньда бәлки, күп-күп эшләр күрдем,
Билгесездер – кая ташлар бу тәкъдирем;
Кая барсам, кайда торсам, нишләсәм дә,
Хәтеремдә мәңге калыр туган җирем.
*Габдулла Тукай*

Туган җир... Туган авыл... Йөрәккә нинди якын һәм кадерле бу сүзләр. Безнең һәрберебезнең газиз туган йорты, нигезебез урнашкан кадерле туган авылы бар. Һәр авылның үзенә генә хас кабатланмас, истә кала торган урыннары күп. Сокланып туймаслык тугайлар, челтерәп ага торган йөгерек чишмә буйлары, җиткән камыш белән капланган сазлыклар, балыклы күлләр, куе әрәмәләр белән уратылган елга үзәннәре, туган ягыбызның кырлары, басулары, шаулап торган урманнары күңелләргә рәхәтлек биреп, туган туфракка мәхәббәт тәрбияли. Кая гына барсак та, нинди генә матур урыннарны күреп соклансак та, туган төбәгебезнең гүзәллеген берни дә алыштыра алмый. Туган ягыбызның һәр сукмагы, һәр агачы, һәр авылы аның барча кешеләре күңелгә ифрат та якын. Тәпиләп киткән, беренче тапкыр әттә-әннә дип әйтергә өйрәнгән вакытта ук күңел түренә туган телебез аша кереп утырган, ул кадерле.

Авыллар, авыллар... Аларда безнең үткән тарихыбызның бер өлеше, халыкның моңы, кайгысы-шатлыгы, куанычлар һәм сагышы. Аларның берләре бик борынгы, икенчеләре шактый соң барлыкка килгән. Һәрберсенең үз үсеш тарихы, үз даирәсе, үз мохите, үзенең данлыклы кешеләре бар. Шуның өстенә авыллар милләтебезгә, халкыбызга җиң сызганып хезмәт итүче кадрлар бирә торган изге урыннар. Авыллар гөрләтеп яшәсә, милләт, халык яшәр, үсәр һәм көчәер.

Еллар узган саен шактый сандагы авылларның беткәнлеген беләбез. Авылларда яши торган күп халык нигезен ташлап китәргә мәҗбүр булды. Авылны ташлап китү сәбәпләре

күп төрле. Байтак кына авыллар урыны уйлап эшләнмәгән сусаклагычлар төзү нәтиҗәсендә суга батырылды. Берничә авылны бер колхозга берләштерү дә күп кенә уртача зурлыктагы гөрләшеп яши торган авылларның тамырын корыту булды. Колхоз һәм совхозның үзәге урнашкан авыллар хәйран матурланды, ә колхозларның бригадаларын хасил иткән авыллар сүнде, кечерәйде һәм алардан халык күченеп китә башлады. Авылларның кайберләре “перспективасыз” га әйләнде һәм әкренләп бөтенләй юкка чыкты. Бер ишеләрнең урыннары сөрелде, икенчеләренең нигезләрендә чокыр-чакыр, череп бетмәгән иске такта-токта аунап ята, кычыткан үсеп урыра. Яшь буын бу урыннарда авыл булганын җөмһүриятебезнең карталарыннан карап кына беләчәк. Шуңа күрә дә авыллар тарихы, һичшиксез, язылырга һәм киләчәк буын вәкилләренә кадерле мирас итеп тапшырылырга тиеш.

Авыллар тарихы турында сүз алып барганда, алар урнашкан мохит турында сөйләү, һичшиксез, зарури.

Билгеле булганча, елга-суларны бабаларыбыз изгеләштергәннәр, аларга табынганнар, гыйбадәт кылганнар, шәһәр һәм авылларын елга-инеш, күл, чишмә-кизләү тирәләренә торгызганнар. Һәр авылның тирә-юнь табигатен берәр яки берничә төр су чыганагы бизи. Халыкның тормышы, көнкүреше су белән бәйле. Су янында урманы, тавы, ышнасы, аланы, тугае, сазлык-баткаклыгы, болыны, коесы, юллары, изге, иске йорт урыннары була. Авыллар турында сөйләгәндә, без аларның тирә-юнендәге географик берәмлекләрне һәм легенда-риваятьләрне, аерым җыр, шигырь юлларын да файдаланырбыз, чөнки алар торак пунктларның тарихын ачыкларга булышалар.

Фәнни-тикшеренү эшенең максаты итеп авылым тарихын һәм аның хәзерге актуаль проблемаларын ачыклау алынды. Шул максаттан чыгып, түбәндәге бурычлар куелды:

1) авылымны тарихи яктан өйрәнү;
2) авылымның хәзерге халәтенә күзәтү ясау.
3) авылының актуаль проблемаларын яктыртуга урын бирү;

**I . Авылым тарихын теоретик яктан өйрәнү.**

Яңа Җөлби авылына 18 нче гасырда нигез салынган (“Татарский энциклопедический словарь “ Казань, 1999г., 402нче бит) Мари теленнән тәрҗемә иткәндә безнең авыл “су башы” дигәнне аңлата. Исбатлап үтәм: Юльба, Юл-река, Яла – вода(слова индо-иранского происхождения), с ненецкого – протока. Борынгы марилар елганы ***юл, юла*** дип йөрткәннәр.

Ба – калку җир, кыр дип тәрҗемә ителә.(Этимологический словарь марийского языка / Ф.И.Гордеев. Под ред. И.С.Галкина Йошкар – Ола, 1983)

Казансу елгасының уң як кушылдыгы Красна елгасы башына урнашкан Яңа Җөлби авылы. Район үзәге Олы Әтнәдән 12 км ераклыкта яшибез. Күршебездә бөек Тукай туган Кушлавыч авылы.

Авылыбыздан 2 чакрым ераклыкта Иске Җөлби авылы урнашкан. Шушы ике авыл арасында “Иске зират” дип аталган каберлек бар. Бу- авылыбызның иң чал тарихын тоткан урын. 1958 елда әле ташлары да сакланган каберләр була. Ташлардагы язуларны укып белүче табылмый. Чөнки алар - бик борынгы язмалар. “1525-50 ел” дип язылган язманы гына укый алалар. Хәзерге көндә ул урында бер кабер саклана. Кабер соңгы елларда чардуган белән әйләндереп алынды. Элек шушы зират турысыннан таш юл салынган. Юл я зират аша, я аның кырыеннан үткән булырга тиеш.

Җөлби атамасы тарихи чыганакларда шактый урын ала. 18 нче йөз мәгълуматларын чагылдырган Д.А.Корсаков җыентыгында Иске Җөлби авылында 71 йомышлы татар яшәгән дип күрсәтелә. Яңа Җөлби дип аталган авылда 130 йомышлы татар исәпләнгән ( Сборник 1908, №№30, 31, 33, б. 249) 19 нчы йөздә (А.Артемьев) Көек яки . Яңа Җөлби авылының 84 хуҗалыгында 337 ир-ат һәм 314 хатын-кыз яшәгән, бер мәчет эшләгән (Список, 1866, №№230, 263, б. 14, 16)

Көек яки Яңа Җөлби авылы турында И.А. Износков болай яза. Авылда 118 хуҗалык булган. Анда 379 ир-ат һәм 378 хатын-кыз яши. Халыкның көн-ае уртача гына. Халык Көек авылы җәмгыятенә кергән, тегермәнчелек һәм кирпеч сугу белән шөгыльләнгәннәр( Список 1885, XIII ,9; XV, 3)1898 елгы китапта күрсәтелгәнчә, Көек(Яңа Җөлби ) һәм Иске Җөлби

авылларында татарлар яшәгән (Список, 1898, №№57, 143, б. 2, 4). К.П.Берстель белешмәсендәге мәгълуматларга караганда, Көек(Яңа Җөлби) авылында 819, Иске Җөлбидә 433 татар кешесе яшәгән( Список 1908, №321, б. 20).[37]

"Җөлби" исеме мари сүзеннән алынган "Су башы" дигәнне аңлата. Чөнки бу җирләргә беренче булып марилар урнашкан. Мәрҗән ягындагы елга кырыенда зиратлары сакланган. Елга буеннан һәр җәй көтү йөрүе аркасында, кайбер каберләрдән кешенең баш сөякләренең күренеп торуы билгеле булды. Кабердән чабата ясау коралы – "шөшле" һәм хатын-кыз чәчен малайлар (Шәймәрданов Рафис) алып кайтып күрсәтеп йөрделәр.

Авыл ике елга арасына урнашкан. Мәрҗән яктан килүче елга "Красна" дип аталган. Бу елганың суы чишмәләрдән генә тора. Мәңгәр ягыннан агучы елга да, чишмәләрдән башланып, "Сәрдә елгасы" дип исемләнгән. Бу якларда куе урман булган, ә су буйлары сәрдә үләне белән капланган булган.

Кешеләр, Кушлавыч ягындагы урманны кисеп, такта ярып сатканнар. Ул елларда лашманчылык көчле булган. Авыл халкы имәннән мичкә ясаган. Бу мичкәләрне хәтта Әтнә базарына барып сатканнар.

Хәзерге Кушлавыч авылына баручы юлның уң як тау башы халык арасында "мичкә бите" дип йөртелә. Бу атама шул вакыттан ук калган. Сәрдә елгасы буендагы күл Мөәзин күле дип йөртелә. Бу күл дә куе урман эчендә булган. Сәрдә суына күп су бирүче Салкын чишмә ике су кушылган урында булган. Бу чишмә Ташлы чишмә дип тә атала. Чөнки аның яр буйларында зур-зур ташлар булып, чишмә шул ташлар арасыннан ургып чыккан.

Безнең авыл яныннан агып киткән Сәрдә суы буена Сәрдә авыллары урнашкан. Красна елгасы да шушы суга кушылып, аның яры буена Красна авылы җәйрәп ята. Бәлки, аның чыгышы безнең авыл белән бәйледер әле. Чөнки Красна елгасының башы безнең авыл янындагы Аппакай чишмәсеннән башлана. Комыргуҗа авылы ягындагы басудан аккан Кугә-чирмә елгасының суы да Краснага кушыла. Күгә-чирмәнең тармагы Мөхтәр елгасы дип аталган. Чөнки ул вакытта бу җирләр Мөхтәр исемле кешенең җире булып исәпләнгән. Хәзерге вакытта бу җирләр Иске Җөлби авылына карый. Мәңгәр авылы ягындагы елгаларның исемнәре Имәнкол, Кобанай, Сапый дигән кешеләрнең исемнәре белән аталган. Атау елгасы, күп сулы булган Атау чишмәсе, Солтангол елгасы, Аппакай тармагы да шулай ук кеше исемнәре белән йөртелгән.

Авыл тирә-яктан куе урман белән капланган. Авылда яшәүче олырак кешеләр болай дип сөйли: "Зәйнулла бабайның "булачак" әти-әнисе урман кисәргә баргач, бала елаган тавыш ишетеп, агач башына эленеп күз салалар. Иң югары ботакта бала салынган бишек күрәләр. Баланы өйгә алып кайтып, аңа Зәйнулла дип исем кушалар һәм үз балалары итеп үстерәләр.(Аңа авылда табылдык дип кенә дәшкәннәр.) Зәйнулланың буыны- Хоббуллина Әминә әле дә исән. Әминәнең әтисе – Нәҗип, Нәҗипнең әтисе – Хоббулла, Хоббулланың әтисе Зәйнулла була.

Авылның бер урамы әле дә Сәрдә башы дип йөртелә. Шушы урамда яшәгән Гомәр абзыйның әтисенең бабасының исеменә язылган җир өчен бирелгән язу 1913 нче елга туры килә. Бу язма хәзерге көнгә кадәр Мөхәммәтшина Әминә апада (Гомәр абзыйның кызында) сакланган.

Халык иген игәр өчен авлның әйләнә-тирәсендә урманнарны кисеп җир хәзерләгән. Күгә-чирмә җире хәзер Олы елга дип аталган елга буенда.

18 нче йөз мәгълүматларында Иске Җөлби авылында 71 эшче татар, ә Яңа Җөлбидә (ул чорда Көек дип аталган) 130 эшче татар булган. 84 хуҗалык булып 337 ир, 314 хатын-кыз яшәгән.

Авыллар зураеп, урманнан җирләр ачылып, халык авыллар белән аралашып яши башлаган. Тарихи язмаларда Җөлби Мәрҗән авылы белән искә алына. 1878 елда 120

---

[37] Ф. Гарипова "Авыллар һәм калалар тарихыннан" Казан, 1997ел 498-499нчы битләр

хуҗалык: 355 ир, 352 хатын-кыз яшәгән. Ә 1898 нче елга караган мәгълүматларда авылда 128 хуҗалык булып 819 татар яшәгәнлеге күрсәтелә. Ул чорда авылның агач мәчете, 4 тегермәне (ярма яргыч тегермәне дә) эшләп килгән. Халыкның тормыш-көнкүреше уртача булган. Халык шулай ук тимерчелек һәм кирпеч сугу белән дә шөгыльләнгән.

Иске Җөлби, Яңа Җөлби, Комыргуҗа, Олыяз һәм Сасмак авыллары халкы бергә җыелышып, Кызыл яр җыены үткәргән. Ул икенче төрле Җөлби җыены, яисә Сасмак җыены дип тә аталган.

Аксакаллар сөйләвенә караганда, авылда чирмеш нәселләре, ягъни мариларның мөселманлык кабул иткән аерым кешеләре яшәп калган. Ләкин халык аларның бабалары мари булганлыгын хәтерли әле. Якын-тирә авыллар ислам динен тотканнар. Чукындыру башлангач та авылга һөҗүм булмаган. Ә менә Шәкәнәч авылы янындагы Норма авыл халкын Байчыга урыслары килеп чукындырып китәләр. Ләкин авыл халкы динен сатмый, икенче килүләрендә попны тере килеш күмәләр. Бу авыл колхозларны эреләндерү чорына эләгеп юкка чыга, халкы тирә-як авылларга китеп яши башлый.

Сәрдә суы буйларында куаклыклар, ә суында балык күп булган. 1970 нче еллар тирәсендә Сәрдә сулыкларыннан мамонт төшләрен табып алып кайттылар (Шәймәрдәнов Фәнис).

Салкын чишмә колхоз көтүе йөреп күмелеп бетү хәленә килде. Авылның ир егетләре чишмәне буралап куялар.

1931 нче елга кадәр аерым хуҗалык булып яшәгән 210 хуҗалыклы авылда колхозлашу чоры башланган. 7 хуҗалыктан торган колхоз төзелә. Беренче председатель Мусин Габдрахман була. Ләкин бу колхоз таркалып, 1933 нче елда яңадан торгызыла. Колхозга "Комсомол" исеме бирелә. Колхоз председателе итеп Шиһапов Солтан сайлана. Колхозда 4 бригада төзелә. Беренче авыл советы рәисе Галиәхмәтов Кадыйр, секретаре Гарипов Габделхак була. Шушы чорда авылларда комитетлар төзелә (комитет рәисе Ибраһимов Хәкимҗан була). Колхоз ул елларда уңыш алуда, башка төр оештыру эшләрендә алдынгы урыннарда йөри. Район "Кызыл юл" исемен йөртә.

1934-35 нче елларда Шиһапов Солтан, Гарипов Габделхак мәктәп төзелешенә зур өлеш кертәләр. Мәктәп хуҗалык өендә була. Беренче укытучы – Гәрәев Газиз абый була. Ул соңгы көннәренә кадәр Арча районының күп авылларында яши һәм укытучы булып эшли, Әтнә районының мәгариф системасында да хезмәт куя.

1941 нче елны Бөек Ватан сугышы башлангач, авылдан 90 ир-егет сугышка китеп, шуларның 60ы үлеп кала. Колхоз ул елларны "Беренче Май" исемен йөртә. Авылда бик авыр чор башлана: ачлык, кияргә кием, ягарга утын юк, ә колхозда эшләргә кирәк. Әтиләрне 11-12 яшьлек малайлар алыштырса, әниләр, апайлар авыр йөкне үз җилкәләрендә тартканнар. 1943 нче елны колхоз рәисе итеп сугыштан яраланып кайткан Шакиров Әхмәтгали абзыйны куялар. Ә авыл советы рәисе булып эвакуация белән кайткан Һава исемле хатын-кыз эшли. Ә мәктәптә бу елларда Һадиев Габделхак абый һәм хатыны Мәрьям апа укыталар. Медпункт Комыргуҗа авылында була (фельдшер – Камалова Сәгъдәт апа).

Бөек Ватан сугышыннан соң авылга укытучы булып ирле-хатынлы Сибгатулла һәм Саҗидә Зимагуловлар килеп урнаша. Алар бик озак еллар балаларга белем бирү өстендә эшлиләр. Сибгатулла абый бик тә итәгатьле кеше була, авыл халкының зур ихтирамына ирешә. Сугышка кадәр 4 нче кластан соң укучылар Югары Сәрдәдә укысалар, соңгы елларда Комыргуҗа 7 еллык мәктәбенә көн дә 5 чакрым араны җәяү йөреп укыйлар. Ул елларда 45тән артык бала йөреп белем ала.

Хәзерге көндә авылда яшәүче (1924 нче елда туган) Насибуллина Миңлевафа апа искә алганнардан: "Почтаны Олы Әтнәдән Югары Сәрдәгә һәм Җөлбигә җәяүләп чиратлашып алып кайта идек. Безнең авылга хатлар Әтнә районы Яңа Җөлби авылы дип тә, Көек авылы дип тә килә иде. Авыл урамнарының исеме: Атлашкин, Түбән урам, Олы урам, Сәрдә башы диеп йөртелде. Ул чорда 2 тегермән, кибет (кибетчесе Сабирова Әминә апай), 193 хуҗалык бар иде. Колхозда эшләү көнлек таякка язылып исәп-хисап ел ахырында гына ясалган. Халык мунчаладан кап сугып түләү түләгән. Халык үзенең хезмәте белән сугышта җиңү өчен

үзеннән зур өлеш керткән. Өсләренә кияргә юньле киемнәре булмаса да, 16-17 яшьлек кызларны урман кисәргә, окоп казырга җибәргәннәр.”[38]

Миңлевафа апа үзенең 4 бертуганы белән 14 яшендә әти-әнисен югалта. 4 туганы аның карамагында кала. 1943 нче елны ул (19 яшендә була) 17 яшьлек энесен сугышка озата. 27 яшендә , үз тиңнәре калмагач, 50 яшендәге кешегә тормышка чыгып 7 бала үстерә. 60 яшенә кадәр колхозда терлекчелектә эшли. Тормышның бик күп авырлыкларын күргән Миңлевафа апа хәзерге көндә дә сәламәтлегеннән зарланмыйча яши, барлык үткәннәрне дә хәтерли. Без аны авылның “аяклы тарихы” дип йөртәбез.

Сугышка кадәр безнең авыл аша үтүче Коркачык – Әтнә юлына таш җәелә башлый. Бу эш кул хезмәте һәм атлар белән башкарыла. Әтнә районында яшәгән, хезмәт чорын башлаган һәр кеше 6 көн юл төзелешендә эшли. Хәзерге чүп базына кадәр юл салына. Сугыш башлангач, калган юлга вак таш җәяләр.

1958 нче елны “Беренче Май” колхозын Олы Әтнәдәге Киров исемендәге колхозга кушалар. Бу колхоз Кече Әтнә, Шәкәнәч, Норма, Яңа Җөлби һәм Олы Әтнә авылларын берләштерә. Колхоз рәисе Бариев Нургали була. 1950 нче елларда авыл Комыргуҗа авыл советына карый. Колхозлар берләшкәч, авылда терлек симертү фермалары төзелә, җигүле атлар да күп була. Ферма мөдире булып озак еллар Хоббуллина Әминә, бригадир булып Шигапов Солтан эшли. Яңа Җөлби бригадасы ул елларда авыллар арасында иген уңышы алуда да терлекләрнең көнлек үсеш бирүендә дә алдынгы урыннанда барды. Әхмәдуллина Кәримулла, Мөхәммәтҗанов Сөнгатулла, Фазуллин Илфарлар механизаторлар арасында алдынгылыкны бирмичә эшлиләр. 1999 нчы елны район буенча үткәрелгән механизаторларның җир сөрү ярышында Гарипов Мөдәрис 3 нче урынны яулады.

Авылда мәчет булса да, төпле белемле дин кешесе булмаганлыктан, халыкның дини белеме түбән булган. Революциядән соң мәчетне клуб итеп тотканнар. Аннан соң мәчет сүтелеп, агачларын ташып якканнар. Мәчетнең 4 стенасы гына торып кала. 1958 нче елда колхоз рәисе Бариев Нургали мәчетне яңадан клуб итеп төзетә. Аңа кадәр клуб ролен хәзерге медпункт бинасы үти.

*1.2. Авылымның хәзерге торышы*

Хәзерге вакытта Яңа Җөлби авылында 23 хуҗалык исәпләнә һәм шуларны 70 кеше тәшкил итә. Авылыбыз әкренләп ташландык хәленә килә.Авылда кибет, клуб, мәктәп ябылды.

Сугыштан соңгы еллардан бирле авылда Сабантуйлар үткәрелеп килә. 2009 нчы елның июнь аенда авылыбызда иман йорты – мәчет ачылды. Мәчет ачылу тантанасына кунаклар, читтә яшәүче авылдашлар күп кайтты.

Авылны күпме яңартырга тырышсалар да, ул барыбер бетү хәленә килә. Чөнки кеше саны торган саен азая. Авылда төпләнеп калучы яшьләр саны юк дәрәҗәсендә, күбесе калага китеп баралар. Авыл халкының күп өлешен өлкән яшьтәгеләр тәшкил итә. Хуҗалары бакыйлыкка күчкән йортлар ябыла. Шулай итеп авылда буш йортлар саны арта бара.

Авылның иң зур проблемасы – юллар булмау иде.Районыбыз белән авыл арасы 12 чакрым. Җәен юллар ярыйсы булса да, кышын бөтенләй юлсыз кала идек. Шул сәбәпле авылда ферма бетте, эшсезләр саны артты. Колхозчылар көн саен иртүк торып, район фермасына эшкә йөриләр

Быел, 2017нче елда, Комыргуҗа авылыннан Яңа Җөлби авылына 5км юл салынды. Балалар Шиһабетдин Мәрҗани исемендәге Комыргуҗа урта гомуми белем бирү мәктәбенә укырга йөриләр. Аларны автобус йөртә.Авыл тарихын өйрәнү – аның килеп чыгышын тикшерү генә түгел, ә татар халкы тарихын, рухи байлыкларыбызны, гореф-гадәтләребезне өйрәнү дә, буыннар арасында ныклы бәйләнеш булдыру, мәгърифәтле милләт булып яшәвебезне дәвам итү өчен төп чара да

*II . Авылымның тарихын өйрәнүенең практик нигезләре*

[2] Насибуллина Миңлевафадан язып алынды.

Фәнни-эзләнү эше – күп вакыт һәм зур тырышлык сорый торган хезмәт. Теманы сайлаганнан соң, хезмәтемнең максатын билгеләдем. Авылның тарихын төгәл ачыклап бирү өчен бик бай материал тупларга тырыштым. Авыл тарихын язуда Фирдәүс Гарипованың “Авыллар һәм калалар тарихыннан” китабы ярдәм итте. Шулай ук архив чыганаклары да кулланылды.

Шәһәр һәм районнар тарихын өйрәнү буенча хезмәтләр шактый. Тарих өйрәнү, әлбәттә, кирәкле һәм изге эш. Иң мөһиме: авылларның үткәнен белү, туган якка кайту юлын онытмаска кирәк. Туган як бит авылдан башлана: аның киң кырларыннан, челтерәп аккан елгалардан, чишмәләрдән, капка төбендә үскән бәбкә үләннәрдән...

Яңа Җөлби авылы бик уңайлы җиргә – тау башына урнашкан. Ул һәр яктан кечкенә-кечкенә елгалар белән уратылып алынган. Елга үзәннәрендә менә дигән көтүлекләр, печәнле болыннар. Ләкин ул печәнлекләрне таптарлык көтүләр безнең авылда калмады инде. Эреле – ваклы елгаларның буеннан-буена көмеш сулы, зәңгәр күзле чишмәләрнең саны исәпсез-хисапсыз. Бүген исә күңелне шунысы сыкрата, каралмау сәбәпле һәм игътибарсызлык аркасында аларның күзләре мәңгегә йомыла... Элек, тормыш күп тапкыр авыррак чакларда да, әби-бабаларыбыз чишмәләрне һәрдаим барлап, кадер-хөрмәт күрсәтеп, тазартып-чистартып торганнар, буралар төшергәннәр. Ә хәзер кая карама техника, ә табигатькә, аерым алганда, чишмәләргә игътибар юк чамасында.

Нәтиҗә:

1. Авылларның тарихын өйрәнү яшь буын өчен бик әһәмиятле. Чөнки галимнәр әйткәнчә, “Туган як тарихын белмичә, алга таба яшәү мәгънәсез...”

2. Бүгенге көндә авылым элекке халәтенә әкренләп кайтып килә. Ләкин барыбер күп проблемалар әле дә хәл ителә алмый әле. Әгәр халык үз туган ягын хөрмәт итә икән, милләт яши. Милләт яшәсә, тел яши, ягъни тормыш дәвам итә.

*Йомгак.*

Авыл тарихын өйрәнү – бик әһәмиятле эш. Дөрестән дә, телдән һәм туган туфрактан башка яши алмаган кебек, без аның тарихыннан башка яши алмыйбыз. Без, әлбәттә, туган авылыбызны саклап калырга тырышабыз. Чөнки монда безнең кендек каныбыз тамган, шушында без беренче тапкыр дөньяга күз салганбыз, шушында туып үскәнбез һәм әле дә шушында яшибез.

Алга таба авылның күп проблемалары чишелер, шәһәрләргә күчеп киткән кешеләр кире туган нигезләренә кайтыр һәм авыл элеккечә гөрләп яшәп китәр. Барысы да безнең ышануыбыздан, тырышлыгыбыздан һәм, гомумән әйткәндә, үзебездән тора.

Фәнни хезмәтне эшләү дәверендә куелган максатка ирештек дип саныйм. Керештә теманың актуальлеге дәлилләнде. Адәм баласы үзенең туган ягын ихтирам итәргә тиеш. Әгәр дә без моны истә тотсак, авыллар юкка чыкмас, ә киресенчә, артуга таба барыр иде.

*Файдаланылган әдәбият.*


1. Гарипова Фирдәүс Гариповна. “Авыллар һәм калалар тарихыннан” Казан, 1997ел
2. Населенные пункты Республики Татарстан Казань, 1997
3. Татарский энциклопедический словарь, 1999г
4. Татарстан АССР тарихы Том 1 Казан, 1959ел

# ФРОНТОВЫЕ ПИСЬМА МОЕГО ДЯДИ ХАМИДУЛЛИНА НАЖИПА

*Зайнутдинова Аделя Рамисовна, ученица 10 класса*
*Научный руководитель – Гатауллина Энджe Ильнуровна,*
*МБОУ «Шеморданский лицей Сабинского муниципального района РТ*

Прошу вас,
Храните солдатские письма,
Они и просты и порою грустны.
В них столько надежды
И вечного смысла.
Прошу вас,
Храните солдатские письма -
Тревожную память
Людской доброты.
*Яков Халецкий*

В каждой семье, в каждом доме есть вещи, которые не имеют возраста и цены, они хранят память о прошлом, оберегаются и заботливо передаются из поколения в поколение… Реликвии – это дорогие сердцу вещи. У кого-то это может быть часы, книга, ваза, картина…

В нашей семье бесценной реликвией являются пожелтевшие письма-треугольники с фронта солдата Великой Отечественной войны - Хамидуллина Назипа Хамидулловича, адресованные моей прапрабабушке - Хаят, родственникам Хание апа и Мунире апа. В них хранится память практически каждого дня, каждого бесценного мгновения жизни солдата во время этой ужасной, кровопролитной войны. Я выбрала эту тему после того, как увидела оригинал писем, написанных в годы войны, и решила узнать как можно больше информации об этой тонкой нити связи в то время.

В наше время мои сверстники имеют мало представлений и знаний о военном времени, военной жизни и военных письмах. Я поставила перед собой цель о возобновлении молодого поколения к изучению и познанию на тему военной жизни. Письма, документы, газеты, фотографии времен Великой Отечественной войны являются важным объектом для изучения военной истории и вызывают большой интерес как письменные исторические источники.

**Новизна исследовательской работы** обусловлена тем, что данный материал, ранее не известный, позволяет проследить судьбу жителя деревне Верхний Отар на фоне исторически значимых событий второй мировой войны.

В процессе исследования я опирались на следующие **источники**: письма из личного архива Хамидуллиной Флеры Назиповны, воспоминания, интернет ресурсы, Книга памяти.

**Объект исследования:** фронтовые письма

**Предмет исследования:** содержание 12 фронтовых писем

В подготовке к выполнению этой работы мне помогала учитель МБОУ «Шеморданский лицей Сабинского муниципального района РТ» Гатауллина Энджe Ильнуровна.

Работа состоит из исследовательской и теоритической части. В теоритической части изучены вопросы о фронтовых письмах, видах писем с фронта. В исследовательской части даны исследования фронтовых писем Хамидуллина Нажипа Хамидулловича с семьей в военное время.

**Цель работы:**

- Собрать, изучить и сохранить информацию о письмах с фронта моего дяди Хамидуллина Назипа

**Задачи работы:**

1. Поиск информации по личности Хамидуллина Н.Х. и его боевого пути.

2. Определить информационные возможности фронтовых писем

**Ожидаемые результаты:**

-Фронтовые письма, как источник информации о воинских частях.

- Документальные сведенья военной эпохи из фронтовых писем.

- Сохранение и трансляция истории последующим поколения.

**Методы исследования:**

- Сбор и анализ информации;
- Исследование писем с фронта;
- Интервью с дочерью ветерана;

**Материал исследований:** При выполнении работы я исследовала оригинал фронтовых писем времен ВОВ из семейного архива Хамидуллиных. Материалы о военных письмах взяты из интернета и научно-популярной литературы, архивных выписок. При написании работы использовались материалы архива Министерства Обороны РФ. Работа выполнялась в период с сентября 2016 г. – сентябрь 2017 г.

**Гипотеза:** мы считаем, что изучение писем с фронта играет большую роль в формировании патриотических, гражданских, нравственных чувств.

## Глава 1. Общее сведения о фронтовых письмах.

Конверт-треугольник — обычно тетрадный лист бумаги, сначала загнутый справа налево, потом слева направо. Оставшаяся полоса бумаги (поскольку тетрадь не квадратной, а прямоугольной формы) вставлялась, как клапан, внутрь треугольника. При резко возросшем объеме переписки недоставало конвертов и открыток. В такой-то обстановке и родился фронтовой "треугольник". Народ его называл солдатским. Готовое к отправке письмо не заклеивалось — его всё равно должна была прочитать цензура; почтовая марка была не нужна, адрес писался на наружной стороне листа.[39]

Какой же путь проходило письмо? Солдат бросал письмо в почтовый ящик, сооруженный из подручных средств и укрепленный в удобном месте. Почтальон части ежедневно выбирал конверты, "треугольники", открытки, секретки и относил на полевую почтовую станцию, там все послания обрабатывались календарными штемпелями и закладывались в мешки, которые транспортом части отправлялись на базу полевой почты. Оттуда корреспонденция, рассортированная по направлениям, передавалась на ВПСП. Дальнейший путь проходил обычными маршрутами в почтовых вагонах.

Важным было сохранение военной тайны: надо было не дать возможности врагу по содержанию писем получить сведения о дислокации частей, их вооружении. Для этого была создана военная цензура. Все письма с фронта в обязательном порядке просматривались, любые спорные места вымарывались чёрной краской. На почтовые отправления ставился штамп «Проверено военной цензурой». Письма либо открытки, адресованные в армию и брошенные в почтовый ящик тылового города, сначала отправлялись в гражданское отделение связи, оттуда в тыловой военно-сортировочный пункт. Затем в почтовом вагоне они отправлялись на фронтовой военно-почтовый пункт, оттуда на военно-почтовую базу армии, оттуда в дивизию, полк, батальон и, наконец, попадали адресату.

Задержка корреспонденции или засылка ее не по назначению расценивались почтовыми органами как должностное преступление. Для военных почт по последствиям это было как приказ "Ни шагу назад!" на передовой.

## Глава 2. Историческая основа писем

Семья Хамидуллиных проживала в деревне Верхний Отар Сабинского района ТАССР. Семья состояла из 4 сыновей (Саитжан (Саид), Камиль, Нажибулла (Назип), Абдулла), трех дочерей (Амина, Хамида и Таифа) и их матери - Хаят. У Саитжана, Камиля, Нажибуллы и Амины были свои семьи. Мой прадед – Ягъфаров Камиль - взял фамилию отца, Ягъфарова Хамидуллы. Остальные дети получили фамилию по имени своего отца.

[39] Материалы Международной научной конференции. «Немцы в Сибири: история, язык, культура» г. Красноярск, 16 октября 2004год

Но мирная жизнь нашего народа, в том числе, и жителей нашей деревни Верхний Отар была нарушена Великой Отечественной войной. В 1941 году из деревни ушли на фронт защищать свою Родину все мужчины и парни, и две девушки. Все молодые и здоровые. Среди них были и наши родственники. Самый старший из братьев Саид, 1900 г.р. был инвалидом по зрению, поэтому его не взяли в армию. Во время войны его с семьей отправили в Бурятию. Второй дядя Абдулла, 1910 г.р.(по документам Абдул Ягафарович или Ягофарович ) был призван на службу 28.12.1941 году. Был телефонистом 415 отдельной роты связи 146 стрелковой дивизии (Приложение №15). Был награжден медалями «За отвагу»[40] (Приложение №16) и орденом «Красная Звезда»[41](Приложение №17).Он дошел до Берлина, так же как и его средний брат Назип, 1905 г.р. Но по воле судьбы, им не суждено было встретиться. Дядя Назип получил ранение прямо перед взятием Берлина и был госпитализирован в 232 отдельной медико- санитарной роте в д. Гросшвейн Бранденбургской провинции Германии. Там он умер 12. 02.1945 (см. Приложение №1). Мой прадед Камиль был 3 раза был участником боевых действий: Первой мировой, Гражданской Великой Отечественной войны. Во время Великой Отечественной войны по приказу (по старости) был отправлен в Москву на работу в автозавод. Трудился там партийным работником. В 1947 году мой прадед Камиль возвратился в свою родную деревню (д.Верхний Отар) и работал председателем колхоза. В 1968 году, выйдя на пенсию, в возрасте 74 лет умер по болезни.

У нас в семье хранятся 12 писем Хамидуллина Назипа.

В своих письмах он желает здоровья своей семье и рассказывает о своей жизни. Почти все его письма начинаются с обращения к родным и близким: «милая мама», «мои родные», «дорогие мои дети» и т.д.

Переписка носит ярко выраженный бытовой характер. В письмах речь идет о тяготах жизни, о работе, о хозяйстве. По содержанию писем понятно, что семья моего дяди – Назип абый - была мало обеспечена. Дядя переживает, что его дети не смогут получить образование. Во всех письмах спрашивает о ценах на продукты и на хлеб. Семья состояла из 5 человек: матери дяди Назипа - Хаят, жены- Муниры, двух сыновей- Карама и Ильдара, дочери- Флеры. Когда началась война, Караму было 9 лет, Ильдару- 6 лет, а Флере всего 3 года. Жена Мунира работала в колхозе.

В деревне Верхний Отар проживали семьи старший сестры- Ситдиковой Амины. У нее было две дочери: Хадия и Хания, также сын Гаяз. Гаяз тоже отправился на фронт. Хания апа была учительницей биологии. Дядя Назип большинство своих писем адресует ей. Именно она сохранила эти фронтовые письма и передала перед смертью дочери дяди – Флере.

С первых дней войны наш дядя отправился на фронт[42]. (см. Приложение№ 2). Обучался в Омском (1-е) военно-пехотном училище им. М.В. Фрунзе. Стал командиром взвода.

Омское военно-пехотное училище (ВПУ) им. М. В. Фрунзе. Оно ведет свою историю от созданных 26.12.1919 в Томске 2-х Сибирских пехотных командных курсов ком- состава РККА. В 1921 г. курсы были преобразованы в 25-ю Томскую пехотную школу командного состава РККА, передислоцированную в 1925 г. в Омск. Название «Омское военное училище им. М. В. Фрунзе» школа получила 16.03.1937. В связи с формированием на его базе 2-го Омского ВПУ, 16.08.1941 г. училище стало именоваться 1-м Омским ВПУ им. М. В. Фрунзе. За годы войны училище подготовило и выпустило около 12 тысяч офицеров.[43]

## Глава 3. Фронтовые письма

Что же представляют из себя фронтовые письма Хамидуллина Назипа?

---

[40] Наградной лист

[41] Наградной лист

[42] Из личного архива Сабирзяновой Гузель

[43] Иванов С. Н. ВОЕННЫЕ УЧИЛИЩА НАРКОМАТА ОБОРОНЫ СССР НА ТЕРРИТОРИИ СИБИРСКОГО ВОЕННОГО ОКРУГА В ГОДЫ ВЕЛИКОЙ ОТЕЧЕСТВЕННОЙ ВОЙНЫ, Новосибирское высшее военное командное училище МО РФ, Новосибирск, 2009

1. Письма мой дядя писал на любой бумаге: тетрадные листы, листочки из блокнота, обрывки любой бумаги.

2. Писал письма простым карандашом, редко чернилами.

3. Каждое письмо проверяла военная цензура. Почти в каждом письме стоит штамп « Просмотрено военной цензурой полевой почты»

4. Посылал письма в конвертах разных по форме и размерам. Самый простой и доступный конверт- это письмо, сложенное в треугольник. Были конверты прямоугольной формы размером 15: 13 (размер почтовой открытки) и конверты вдвое меньше указанного размера.

5. Все письма написано на татарском языке, кириллицей.

6. Письма адресовано сестре, жене и матери. Читать и писать из них могли только двоюродная сестра- Хания апа. Мать – бабушка Хаят знала арабскую графику, а жена- Мунира апа, прошла ликбез, получив образование на латинице.

Все письма проверяла военная цензура с учётом требований постановления ГКО «О мерах по усилению политического контроля почтово-телеграфной корреспонденции» от 6 июля 1941 года[3], которое запрещало сообщать в письмах многие сведения, прием и посылку почтовых открыток с видами и наклеенными фотографиями, со шрифтами для слепых, кроссвордами, шахматными заданиями. Запрещалось употребление конвертов с подкладкой. Объем письма не должен был превышать четырех страниц формата почтовой бумаги. Все военные цензоры подчинялись вышестоящим начальникам во главе с Отделом военной цензуры Генерального штаба. Цензурная работа была объявлена секретной и все цензурные изменения, вычерки и изъятия могли быть известны, помимо цензора, только редактору, его заместителю и их прямым начальникам.

В приказе НКО № 0451 от 16 декабря 1943 г. «О введении в действие положения о военной цензуре в Красной Армии»[44] был приведен перечень запрещенных тем, которые не должны были фигурировать ни на страницах фронтовых писем, ни на страницах периодических изданий. Под запретом оказались сюжеты, связанные с мобилизацией, организацией, дислокацией,

боевой подготовкой, боевыми действиями, в том числе военно-географическое и статистическое описание театра военных действий, сведения по его подготовке, оперативной емкости и описание операционных направлений, прямые, косвенные или частичные данные об общем плане операции или боя, о районах и плане сосредоточения и развертывания войск для предстоящих действий и др.

Кроме того, нельзя было писать о боевых действиях партизан, о вооружении, о дисциплине и политико-моральном состоянии войск.

Под запретом также оказались сообщения о материальном обеспечении армии, о путях сообщения, о санитарных и ветеринарных вопросах, об оборонительном строительстве, об организациях, содействующих обороне страны. Эти ограничения отразились на информативности и степени полноты фронтовых писем.

**Что рассказали нам исследуемые письма?**

24.09.1941. Письмо №1

Это письмо адресовано матери, жене и детям. Нажип абый очень скучает по ним. «Уже прошло 3 месяца, а вы ни разу мне не писали. Наверное, думаете, что я все равно не вернусь»- пишет он с упреком. Из письма мы узнаем, что он находится в городе Бузулук. Этот город находится в Оренбургской области. В условиях войны город стал «кузницей резервов» для Красной армии. В городе формировались воинские соединения: 200, 293 и 348 стрелковые дивизии, а также две иностранные воинские части. Нажип абый интересуется здоровьем матери. Спрашивает, не получали ли письма от Гимадия и Камиля. Говорит, что он счастливчик: «4 раза подготовились на отправку, но по неизвестной причине, отправка

[44] Постановление ГКО от 6 июля 1941 г. «О мерах по усилению политического контроля почтово-телеграфной корреспонденции» // Военно-исторический журнал. – 1992. – № 2. – С.35

откладывалась. Через месяц нас должны перевести на новое место. Мы здесь были самыми старшими, сейчас к нам начали отправлять 45 - летних. Если бы получил весточку из дома, не жалко погибнуть в бою. Не смогли ли вы отправить мне немного табака и трехпалую перчатку?» (см. Приложение № 3).

4.02.1942 Письмо №2

Дядя Нажип пишет: «Получил ваше письмо 4 февраля, большое вам спасибо. Очень обрадовался тому, что с вами все хорошо. Все отправил письма и Таифе апа, и Саид абый, и Камиль абый, и Абдулу. Только вы мало пишете. Это первое ваше письмо, после моего перехода на новое место» (см. Приложение №4).

10.05.1942 Письмо№3

Письмо пропитано любовью и заботой о близких и родственниках. Очень сдержанно пишет о чувствах к жене Мунире, так как обижается, что не обучает старшего сына Карама: « Я не доволен тем, что Карам не учится. Меня не надо ждать, может я … Поэтому, надо учиться. Почему вы не пишете, сколько там у вас стоит хлеб? Как мамочка? Не болеет? Дай Бог ей длинную жизнь, может и я вернусь… Но здесь наша жизнь подобно жизни бабочки. Абдул и Зариф живы. Брат Гаяз, напиши письмо. А мое письмо отдай Мунире» (см. Приложение №5).

07 .1942 Письмо №4

Нажип абый отвечает на письмо, полученное 13 июля: «Учеба должна закончиться к 1 августу, может и пораньше. Куда отправят, неизвестно… Узнал о том, что брат Камиль ездил домой. Гимади ранен. Здесь урожай хороший, идут дожди. Желаю вам здоровья» (см. Приложение №6).

27.08.1942 письмо №5

Назип абый пишет матери и жене из города Калинин: «Получил сильное ранение. Из фронта отправили на автомобиле 30 км, потом 100 км. на самолете, долгое время на поезде. Месяц лежу, никак не выздоравливаю» (см. Приложение №7).

12.01.1943 Письмо№6

Это письмо адресовано сестре Амине. Передает привет матери, жене Мунире, детям: Караму, Ильдару и Флере. Также пламенный привет родственникам. Пишет о том, что находится после госпиталя, неподалеку от Омска. «Заданий не так много. Приходят ли письма от братьев Камиля, Саида и Абдуллы? Кто ушел на фронт, а кто вернулся? Про всех напишите. Дорого ли стоит хлеб и продукты?» (см. Приложение №8).

24.01.1943.Письмо№7

Письмо с фронта без конверта (треугольник) на квадратном листе бумаги, сложенном вчетверо, от 24 января 1943 года. "От Назипа. Привет моим самым близким родственникам: Хание, маме, сестре Амине, также жене Мунире, всем детям. Я жив и здоров. Пока можно сказать отдыхаю. Раз в неделю выполняю задания старших командиров. А сам я мл. лейтенант, командир взвода. Обучаем молодых бойцов. Со мной служит тов. Романов из Казани. ..." Полевая почта 1901, часть 132. (см. Приложение №9).

20.021943 год. Письмо №8

Из Омска. Адресовано племяннице Хание: «Сам жив и здоров. Как наши поживают? Как мама? Дети? Оказывается, Касим вернулся. Губай, Муллаян где, Котдус[45] в каких краях? Есть ли весточки от них? Как сами поживаете? Держите ли корову? Как с кормами?» (см. Приложение №10).

Мне стало интересно судьба людей, которые упоминаются в письме. Вот что мне удалось найти:

-Ибатуллин Кутдус Ахметович, 1904 г.р. ст. политрук -8.05.1942- погиб

-Идрисов Гимадей,1908 г.р. с.В.Отар ушел на фронт 14.07.1941

[45] Центральный архив министерства обороны РФ
ЦАМО РФ Оф.58,Оп.18003,Д.322

13.12.1943 Письмо №9

Переживает, что нет писем. «Мама ,наверное, уже состарилась. Не болеете? Как там с питанием и топливом? Письма получаю только с Абдула и от сестры Таифы». Ругает двоюродную сестру за то, что не писала о возвращении брата Гаяза: «Почему вернулся Гаяз? Очень сильно болеет? Почему вы об этом мне не пишете?» (см. Приложение №11).

27.03.1944 Письмо №10

Нажип абый пишет: «Учеба закончилась. Месяц лежал в больнице, сейчас потихоньку выздоравливаю» (см. Приложение №12).

1944 год. Письмо №11. Это последнее сохраненное письмо Нажип абый.

Письмо адресовано матери: «Дорогая мама. Прими мой пламенный привет и пожелания жить во здравии. Передайте привет моим сыновьям Караму и Ильдару, также доченьке Флере! Я живу хорошо, за меня не беспокойтесь. Был на командировке, 15 километрах от нашей части. Пишете, что некоторые люди возвращаются из фронта. Вы на людей не смотрите. Люди разные бывают и обстоятельства тоже. В тех местах, где я нахожусь времени очень мало. Во- вторых, я командир, сами знаете. Ездить домой не полагается. Я отправляю вам 2 фотографии. Одну отдайте моей семье. (см. Приложение №13). Сестра Хания, Вы пишете, что дети приходят учиться не подготовленными. Конечно, дома не повторяют. Их мать не образованная, поэтому, сестра Хания, я поручаю тебе взять на себя заботу за обучения моих детей. Как он поживают? Есть ли у них одежда? Есть ли карандаши? » (см. Приложение №14).

## Глава 4. Воспоминания Хамидуллиной Флеры

*У моего дяди осталась в живых только дочь- Хамидуллина Флера. Она сейчас живет в деревне Кошкино Кукморского района. Я обратилась ней, чтобы она рассказала мне про свое детство. Вот что она нам рассказала: «Я родилась 10 сентября 1937 года в деревне Верхний Отар Сабинского района. Мне было всего 3года, когда отец ушел на войну. Я практически не помню своего отца. По рассказам матери, он был хорошим семьянином. Очень любил нас –детей. Мама работала в колхозе. Рано утром, в 4 часа, она забирала нас с братом Ильдаром с собой на поле.*

*В доме, в 1941 году, у нас жили эвакуированные- москвичи. Впервые у них я увидела и попробовала рис. Он показался слаще конфет. Мама всё время была на работе - заготавливала лес, работала в поле. По вечерам женщины деревни собирались в нашей избе, вязали носки и варежки для фронта. Мой старший брат Карам при лучине читал им вслух, а они вязали. Мы никогда не наедались. Всё время хотелось есть. Жили очень тяжело: ели лебеду, очистки картофеля натирали на терке, пекли хлеб. Хлеб казался таким вкусным! Нам давали один кусок в день. Всегда хотелось есть. Еще корова была, но молоко сдавали государству.*

*В детстве помню, мы собирались около школы. Техничка Файза апа раздавала клочки бумаг. Карандашей не было, писали сажей. Настоящих игрушек у меня никогда не было. Из войлока делали куклу и играли. Зимой было очень холодно. Дров не хватало. Топили солому, она не согревала печь. Трескались окна от холода, ставили бычий пузырь или подушкой закрывали.*

*Да. Было очень трудно. Но, слава Богу, мы дожили до старости. Мне уже 80 лет. Цените свою жизнь. Цените мир, ведь за него многие люди жизнь отдали»*[46].

## Вывод

Я исследовала письма моего дяди - Хамидуллина Назипа – бойца Великой Отечественной войны. Эти письма, являются основным источником знаний и повествований того времени.

Пожелтели от времени проносившиеся до дыр солдатские треугольники, открытки с рисунком и надписью « Победим врага!», выцвели чернила, и от этого они стали ещё ценнее,

[46] Из личного архива Сабирзяновой Гузель

дороже: ведь их писала живая человеческая рука моего родственника, у которого билось сердце, работала мысль.

В наше время, к сожалению, находится немало людей, которые пытаются преуменьшить роль России, вооруженных сил в разгроме фашизма, затушевать, предать забвению массовый героизм советских людей при защите Родины, исказить роль России в войне 40х годов.

Поэтому очень важно в наше время сохранить правду о войне 1941-1945 годов, правду о нашей Победе, сохранить в своих душах и сердцах память о ней и передавать эту память другим поколениям.

Мы своей целью ставили изучение содержания этих писем военного времени.

О людях, которые живут рядом с нами, об их судьбах, о жизни в военные годы я почти ничего не знала. Но в ходе работы над исследованием узнала много о военном времени, о людях, внесших свой бесценный вклад в Победу над фашизмом. Теперь с этой информацией я должна познакомить как можно больше людей. В этом заключается **практическое значение** моей работы. Я считаю, что данную работу можно использовать на уроках истории, классных часах, посвященных Великой Отечественной войне и труженикам тыла, чтобы наше поколение ценило мирную жизнь.

*Список использованной литературы:*

1.Артиллерийский корпус прорыва // Великая Отечественная война 1941—1945. Энциклопедия / под ред. М. М. Козлова. — М.: Советская энциклопедия, 1985. — С. 65. — 500 000 экз.

2.Кондратов В.А. Говорят погибшие герои. Предсмертные письма борцов с фашизмом

3.Материалы Международной научной конференции. «Немцы в Сибири: история, язык, культура» г. Красноярск, 16 октября 2004год Твардовский А.Т. Я убит подо Ржевом

4.Маршак С. Я. Почта военная

5.www.wikipedia

6.Письма из личного архива Хамидуллиной Флеры

7.Из личного архива Сабирзяновой Гузель

8.www. http://podvignaroda.ru

## ОРДЕНЛЫ БАБАМ- ГАИЛӘБЕЗ ГОРУРЛЫГЫ

*Закиров Ильсаф, ученик 6 класса.*
*Научный руководитель- СамигуллинаАльфинурХафизовна,*
*МБОУ «Нуринерская СОШ Балтасинского*
*муниципального района РТ*

Мин кечкенәдән сугышлы уйнарга яратам. Минем уенчык танк-машиналарым, пистолетларым бар иде. Күрше малайлары белән сугышлы уйнап, елап кайткан чакларым да күп булды. Канаган бит, сыдырылган аяк-куллар...Әни гел әйтә килде: “Улым, “сугышлы” уйнагач кемдер җиңелә, кемдер җиңә. Сугышта еламыйлар, батыр бул”. Сугышта батыр булырга кирәк икәнлеген шул вакытта белдем. Тора-бара олыларның “Сугыш кына була күрмәсен!” дигән сүзләрен ишетә башладым. Мәктәпкә укырга кергәч, сугышның нинди куркыныч сүз икәнгеген тирәнрәк аңлый башладым.

Сугыш... 5 хәрефтән торган сүз, ләкин үз эченә нинди куркыныч вакыйгаларны сыйдырган ул. Тиздән илебез Бөек Җиңүнең 73 еллыгына әзерләнә. Мин дә сугыш турында бик күп беләм. Уку улы башыннан ук инде “Үлемсез полк” акциясендә катнаша башладык. Гаилә шәҗәрәсен төзеп, тагын бер кат бабайларыбыз турында мәгълүматларны тирәнәйттек. Бу эш башта авыр тоелды, ләкин сугышта бик авыр булган бит. Безгә, оныкчыкларга, бары

тик сугыш ветераннарының исемен мәңгеләштерәсе генә. Шунлыктан, мин бу эшкә чын йөрәктән алындым.

Әни ягыннан бабам Зәкиев Мәгъсүм Зәки улы сугышта катнашкан,бик күп яралар белән исән-сау әйләнеп кайткан ул. Бабаем турында мин беренче мәртәбә язам, моңарчы апам Илзирә аның турында иншалар гына язган. Бу эштә әнием дә бик булышты. Иҗади эшемнең төп **максаты** - олы бабамның сугышчан батырлыгын өйрәнү. Эшемне башкарганда түбәндәге алымнарны кулландым: гаилә фотолары, гаилә архивы, бабамның документларын өйрәнү.

Әнием ярдәме белән "Үлемсез полк" сайты аша алынган, моңарчы беребезгә дә таныш булмаган мәгълүмат миндә бабам турында язарга этәргеч булды. Аның турында бар кеше дә ишетергә тиеш. Бу эшем бабам рухына дога булып барыр, аның батырлыгын киләчәк буынга горурлык белән тапшырырмын. Музей өчен дә файдалы булыр дип уйлыйм.

*Төп өлеш*

Олы бабам Зәкиев Мәгъсүм Зәки улы 1917 нче елның 28 декабренда Нөнәгәр авылында туган. Ул тугач, гаиләләре белән Акман авылына күченгәннәр. Олылар әйтүе буенча, авылда янгын булган, күп гаиләләр Акман авылына киткәннәр. Бүгенге көндә ул авыл юк инде. Бабай 7 класс белемне Чутай мәктәбендә ала. Шуннан соң ул белемен Арча педагогия училищесында дәвам итә. Тик бабам анда 2 курс кына укый ала. Гаилә хәле буенча ул укуын тәмаламыйча кайтырга мәҗбүр була. Кайткач та, 1938 нче елда Шәмсеҗиһан исемле кызга өйләнеп, матур гаилә корып җибәрә. Шул елны ук Чутай мәктәбендә укытучы булып эшли башлый. Бабамның укытучылык белән шөгыльләнүе турында документлар да, әбием белән язылышу таныклыгы да гаилә архивында сакланган (Кушымта №1)

1939 нчы елда армиягә алына. Бабай башта Монголиядә хезмәт итә. 1940 нчы елда офицерлар әзерләү мәктәбендә укый. Сугышны Чита шәһәрендә каршылый. Сугышка Калинин фронтының 22 нче гвардия дивизиясе составында кереп китә. Бабай бик укымышлы, сәясәтне яхшы белгән, кешеләр белән аралаша белүе белән аерылып торган. Фронтта ул политрук, миномётчылар взводы командиры булган. Сугышта күрсәткән батырлыклары өчен, лейтенант дәрәҗәсенә ирешә. 1944 нче елның 15 январенда икенче Прибалтика фронтында каты яралана. Котельнич шәһәрендә озак кына яраларыннан айный алмый, кире аны сугышка алмыйлар. Бабам турында моңарчы шушыннан артык мәгълүмат юк иде. Хәрби билетларын әнием әле дә кадерләп саклый.( Кушымта № 2)

Гаилә архивын актарам. Бабамның Кызыл Йолдыз ордены, бик күп медальләре сугыш кайтавазы булып торалар. Бу орден-медальләр нинди батырлык өчен бирелгәннәр соң? "Сугыш турында сөйләргә яратмый иде ул, шуңа күрә без аның нинди батырлыклар эшләгәнен дә белми калдык"- дип сөйли әнием. Безгә ярдәмгә "Үлемсез полк", "Подвиг народа" сайтлары килде. Бабай турында мәгълүматлар алгач, бик сөендек без. Нинди батыр булган икән бит минем бабам! Ә үзе нинди гади, сабыр иде.

"Үлемсез полк" сайты аша бабамның "За боевые заслуги" медале, "Кызыл йолдыз" орденын бирү турында бүләкләү таныклыгы, ни өчен бирелгәнлеге язылган документлар табылды. ( Кушымта №3) "За боевые заслуги" медале 1943 нче елның 29 апрелендә Сталин приказы белән бирелгән. Кыскача нинди батырлык күрсәткәне тасвирлана. "1943 нче елның 23 февралендә гвардия кече лейтенанты үзенең взводы белән Смоленск өлкәсе Локнян районы Барст аылын азат иткәндә немец автоматчыларына каршы атакага күтәрелә һәм үзенең минометы белән 15 немец солдатын һәм офицерын юк итте, 28 нче февраль көнендә Зәкиев Мәгъсүм Зәки улының фашист автоматчыларының контрһөҗүме вакытында ситуацияне тиз кулга алуы, тәвәккәллеге нәтиҗәсендә үз взводы белән 40 немец солдатын һәм офицерын юк итте". Укытучым миңа 1941-1943 нче елгы Чепья районында чыккан «Коммунар» газетасында бабам турында фронттан килгән хатны күрсәтте. (Кушымта № 4 ) Бу хатны часть командиры В.Д.Голев язган. Ул хатын Зәкиев Мәгъсүм кебек сугышчылар белән без горурланабыз дип тәмамлый.

Кызылгвардиячеләр бер метр җир, кечкенә генә бер өй өчен дә үзләрен аямыйча көрәшкәннәр. “Кызыл йолдыз”ордены да Смоленск өлкәсе Ромашково авылын азат итү сугышларындагы батырлыклары өчен бирелгән. Бүләкләү таныклыгында 1943 нче елның 12 октябре датасы тора. ( Кушымта №5)Бу батырлыгын сурәтләгән документ та сакланган. Менә нәрсәләр язылган анда: “ Смоленск өлкәсе Ромашково авылы өчен барган сугышта Зәкиев Мәгъсүм взводы һөҗүм итү урынын бик тиз үзгәртеп, немецларга каршы көтмәгәндә һөҗүм итә. Каушап калган немецлар атуны туктаталар, шуны гына көтеп торган кызылгвардиячеләр атакага күтәрелеп, авылны азат итәләр. Немецлар яралы солдатларын алып качалар. Зәкиев Мәгсүм взводы калкулыкта качып атып ятучы 15 немец солдатын һәм офицерын юк итә”. Бабайның орден белән бүләкләнү документының башында менә болай язылган: “ От имени Президиума Верховного Совета Союза ССР, за образцовое выполнение боевых заданий командования на фронте борьбы с немецкими захватчиками и проявленными при этом доблесть и мужество награждаю”. Приказга шул чор дәүләт башлыгы И.В.Сталинның кулы куелган. Бабамның батырлыгын югарыда да бәяләгәннәр.

Тылдагыларны һәрвакыт җиңүгә рухландырып, фронттан килгән хатларны бастырганнар. Мәсәлән, бабамның сугышчан дусты белән фронттан җибәрелгән хаты белән танышып укыгач, аның шул чор өчен никадәр көчкә ия булуы турында шик калмый:

*“Кадерле иптәшләр! Без сезгә, райондашларыбызга, Кызыл Армиядән ялкынлы сәлам җибәрәбез.*

*Иптәшләр, безгә, кызыլармеецларга, СССРның барлык почмакларыннан илдә мул иген уңышы өлгерүе турында хәбәрләр килә. Бу уңышны вакытында яхшы сыйфатта җыеп алу сезнең быел аеруча тырышып эшләвегез Һәм югары дисциплиналы булуыгыз таләп ителә. Быел күп кенә колхозчылар фронтка алынды. Авылда эш көчләре кимеде. Сез, колхозчы иптәшләр, стахановчыларча эшләү белән бу кимүне тутырыгыз, игеннәрне тиз һәм яхшы итеп урып-җыегыз, илебезнең оборонасын һәръяклап ныгытыгыз.*

*Без, кызылармеецлар, дошманны тәмам җиңгәнчегә кадәр, аны тулысынча тар-мар иткәнчегә кадәр актык каныбызгача сугышырбыз.*

*Фашизм җиңеләчәк!*

*Фашизмга үлем!*

*Кызылармеецлар: Зәкиев Мәгъсүм, Латыйпов Мансур”.*

Сугыштан килгән хатлар тылдагыларны рухладырган, алар минем бабам кебек батыр сугышчыларга тиңләшер өчен “Барысы фронт өчен, барысы да җиңү өчен!” дигән девиз астында көн-төн эшләгәннәр.

Гаилә архивында бабамның “За отвагу” медале дә бар. Интернет мәгълүматларына караганда, бабайныкы кебек медальләр 1938 – 1943 нче елларда гына бирелгән. Аннан соң медальнең тышкы рәвешен үзгәрткәннәр. Аның ни өчен бирелгәне турында без мәгълүмат тапмадык. Бу орден да аның оста командалык итүе өчен бирелгәнлеге турында шигем юк.

Мин бабайны хәтерлим әле, миңа аның алдына еш менеп кунаклый идем, ләкин кечкенә йөрәгем аның сугыш турында сөйләгәннәрен кабул итә алмаган. Шул кичләрнең берсендә ул гаиләгә кыры кителгән медаль тарихы турында сөйләгән. Бу медаль аны немец пулясыннан алып калган булган. “За боевые заслуги” медален бирү турындагы документта бабамның инде мондый медале барлыгы турында язу бар. Бәлки шул медаль турындасүз барадыр?

*Бабамның орден – медальләре*

- “За отвагу” медале 09.04.1943
- “Кызыл Йолдыз” ордены 11.10.1943
- “ За боевые заслуги” медале 01.01.1943
- “За победу над Германией в Великой Отечественной войне” медале 21.07.1946 (Указ Президиума Верховного Совета СССР от 09.05.1945)
- “За доблестный труд в Великой Отечественной войне” медале 7.03.1946 (Указ Президиума Верховного Совета СССР от 06.03. 1946)

- “20 лет победы в Великой Отечественной войне 1941-1945 гг.” медале 30.01.1965 (Указ Президиума Верховного Совета СССР от 07.05.1965)
- “30 лет победы в Великой Отечественной войне 1941-1945 гг.” медале июль 1976 (Указ Президиума Верховного Совета СССР от 25.04.1975)
- “60 лет Вооруженных сил СССР” юбилей медале 11.12.1979 (Указ Президиума Верховного Совета СССР от 28.01.1978)
- “Ветеран труда” медале 7.01.1980 (Указ Президиума Верховного Совета Татарской АССР от 12.12.1979
- “Орден Отечественной войны” Iстепени (Указ Президиума Верховного Совета СССР от 11.03.1985)
- “ 40 лет победы в Великой Отечественной войне 1941-1945 гг.” медале 29.04.1985 (Указ Президиума Верховного Совета СССР от 12.04.1985)
- “70 лет Вооруженных сил СССР” юбилей медале 23.02.1989 (Указ Президиума Верховного Совета СССР от 28.01.1988)
- “50 лет победы в Великой Отечественной войне 1941-1945 гг.” медале 22.03.1995
- “Медаль Жукова” 19.02.1996 (Указ Президента Российской Федерации от 19.02.1996)
- “Фронтовик 1941-1945” билгесе(Российский организационный комитет по подготовке и проведению празднования 55-й годовщины Победы в Великой Отечественной войне 1941-1945 годов)
- “60 лет победы в Великой Отечественной войне 1941-1945 гг.” Юбилей медале 5.03.2005 (Указ Президента Российской Федерации от 28.02.2004)

Бу орден-медалләрен тагып Бөек Җиңү бәйрәменә бара иде бабам. Хәзер алар хуҗаларын сагынган кебек, кадерле ядкар булып иң кадерле урында сакла624налар (Кушымта № 6).

Сугыштан бик каты яраланып кайтканнан соң, бабам авыл советы председателе булып эшли, шулай ук мәктәптә дә укыта ул. Бәлки аның оештыру сәләте оныкларына да күчкәндер. Бабамның килене, минем әбием гомере буе рус теле һәм әдәбияты укытты, Әнием дә аларның һөнәрен дәвам итә, математика фәненнән белем бирә.Бәлки, без дә укытучылар династиясен дәвам итәрбез.

1961 нче елда бабам колхозда эшли башлый һәм пенсиягә кадәр фидакәр хезмәт куя. Аның хезмәт кенәгәләре дә гаилә архивында саклана.

***Йомгаклау***

Бөек Җиңү бәйрәменә санаулы көннәр генә калды. Бу олы бәйрәмгә мин дә үземнән өлеш кертә алдым дип уйлыйм. Беренче тапкыр мин бабаем турында сөйлим, аның батырлыгын өйрәндем. Бу эшемне мин туганнарыма да тапшырырмын. Безнең беребезнең дә бабайны онытырга хакы юк. Ул гаиләбез горурлыгы булып мәңге яшәр.

Эшне башкарганда мин нинди максатларга ирештем соң?

1. Гаилә шәҗәрәсен төзү алымнарына төшендем.
2. Сугыш ветераны олы бабам Зәкиев Мәгъсүмнең сугышчан юлын өйрәндем.
3. Бабамның орден-медальләре бирелү тарихы турында мәгълүматлар таптым

Ачылмый калган серләр дә калды: “За отвагу” медале бирелү тарихын белмибез. Ә бит сугышта күпме кеше һәлак булган. Җиңеп кайткан сугышчылар да орден-медальләрен эзләп йөрмәгәннәр. Алар сугыштан соңгы җимерелгән авыл,шәһәрләрне торгызганнар, заводларда, кырда көн-төн эшләгәннәр.Иясенә барып җитмәгән орден-медальләр дә күптер әле. Димәк, сугыш тарихын өйрәнү, батырларны барлау Бөек Җиңүнең 70 еллыгыннан соң да дәвам итәр. Мин дә бабамның сугышчан юлын өйрәнүне дәвам итәрмен. “Үткәнен белмәгәннең киләчәге юк” диләр бит. Бабам белән төшкән фотоларны да кадерләп саклармын ( Кушымта №8).

Сугыш турында минем фикерем анык инде. Сугышлар кабатланмасын, мылтыкларны бары армиядә хезмәт итүчеләр тотып кына карасыннар иде. Җирдә тынычлык булсын, барлык милләтләр тыныч яшәсен!

*Кулланылган чыганаклар*
1.1941-1945 нче елгы Чепья районы “Коммунар” газеталары. Милли архив, Казан.
2. Гаилә архивы материаллары
3. “Подвиг народа” сайты, http://www.podvig-naroda.ru
4.“Победители. Солдаты Великой отечественной войны”, http://www.pobediteli.ru/russia/povolzhye/tatarstan

## МИН ЯШӘГӘН УРАМ ТАРИХЫ

*Зиннатуллина Дина Камиловна, ученица 8 класса*
*Научный руководитель – Закирова Лилия Ахатовна*
*МБОУ "Нижнеметескинская СОШ"*
*Арского муниципального района РТ*

Әй Мөндешем, Мөндешем,
Минем алтын-көмешем.
Бакчада кызарып пешкән
Иң-иң татлы җимешем.
Әй Мөндешем, Мөндешем,
Минем йөрәк тибешем.
Синдә тудым, синдә үстем
Сиңа кайтып килешем, -

дип яза үзебезнең урам кызы Ризәлә апа Гатауллина шигырь юллары белән. Арча районы Мөндеш авылын, туган авылымны бик яратам мин. Авылыбыз шактый зур. Мин яшәгән урам тарихын авыл тарихы дип атап та була: ул төп урам, иң озын урам.

Мин уземнең авыл урамнарын бик яратам чөнки мин иптәш кызларым белән шушы урамнарда уйнап үскән кыз. Җәй көне урамнарда бала-чагалар тавышы өзелми: алар һәрвакыт дуслары белән велосипедта узышалар, туп куалар. Ә кыш көне, мәктәплərдән өйләренә таралышкач, чана-чаңгыларын кулларына тотып тауга чыгып китәләр. Безнең яратып йөри торган тавыбыз Шәйми тавы дип атала. Анда кышын бала-чагалар көн саен диярлек килә. Ә кичен гаиләләре белән чаңгы-чана шуучылар да бар.

Эзләнү эшемнен ***максаты***: туып-үскән урамым, Татарстан урамы турындагы белемнәрен киңәйтү, материал туплау.

Түбәндәге ***бурычларны***билгеләдем:
-туган авылымның һәм урамымның килеп чыгышын өйрәнү;
- авылның, урамның географик урынын, аның атамаларын тикшерү;
- урамдагы төрле биналар тарихын өйрәнү.

Эш барышында авыллар тарихы китаплары белән таныштым, интернеттан авыл, безнең урам тарихына кагылышлы материалларны эзләдем. Иң күп материалларны мәктәп музеенда һәм әтиемнән, аның өлкән абыйларыннан сорашып белдем.

Туган авылым Мөндеш Арча районына карый, ул район үзәге Арчадан 9 чакрымда, авыл Советы үзәге Күпербаш авылыннан - 12, Казаннан 75 чакрым ераклыкта урнашкан.

Д.А.Корсаков җыентыгында әйтелгәнчә, Мөндеш суы ярына утырган Карачүрмә авылында (тарихи хезмәтләрдә ул икенче исеме белән - Олы Мөндеш дип тә әйтелә) 76 йомышлы татар көн иткән. Шунда ук тагын Карачүрмә, йорт-җирләре белән торучылар дип (тарихи хезмәтләрнең кайберләрендә аның икенче исеме Кече Мөндеш) 70 йомышлы татар яши торган икенче авыл да искә алына (Сборник 1908, №148, б.257). А.Артемьев хезмәтендә Мөндеш авылына мондый сыйфатлама бирелә: Ия суы янына урнашкан бу авылдагы 41

хуҗалыкта 237 ир-ат һәм 242 хатын-кыз яшәгән, мәчет берәү булган. Карачүрмә (Йорт-җирләре белән торучылар, Кече Мөндеш). 42 хуҗалыкта 173 ир-ат һәм 179 хатын-кыз көн итә. Халык Карачүрмә авылы җәмгыятенә керә. Карачүрмә (Олы Мөндеш, Мөндеш суы янындагы авыл) халкы Мөндеш авылы җәмгыятен төзи. Авылда барлыгы 66 хуҗалык булып, анда 291 ир-ат һәм 286 хатын-кыз яши. Авылда бер агач мәчет һәм су тегермәне эшләгән. Ике авыл да Ия суы буена утырганнар. И.А.Износков хезмәтендә Мөндеш авыллары турында түбәндәге мәгълүматлар бар. Ия суы буена, Себер элемтә юлының сул ягына урнашкан Карачүрмә (йорт-җирләре белән яшәүчеләр, Кече Мөндеш, Мөндеш авылы-болар Карачүрмә авылы атамасының төрдәшләре) авылында 50 хуҗалык булып, анда мөселман дине тотучы 178 ир-ат һәм 196 хатын-кыз исәпләнгән. Алар Карачүрмә авылы җәмгыятен тәшкил иткәннәр. Халык киндер сугу өчен кирәк-яраклар һәм арба ясау эше белән шөгыльләнгән. Ия суы буена, Себер элемтә юлының сул ягына урнашкан Карачүрмә-Мөндеш суы буена утырган авыл, Олы Мөндеш. Авылдагы 73 йортта мөселман дине тоткан 317 ир-ат һәм 295 хатын-кыз исәпләнгән. Халык Мөндеш авылы җәмгыятенә кергән, тормышлары уртача булган, киндер сугу өчен кирәк-яраклар, арба ясау һәм умартачылык белән шөгыльләнгәннәр. Авылда су тегермәне эшләгән.

1898 елгы хезмәттә Карачүрмә һәм Мөндеш авыллары икесе дә искә алына аларда татарлар яши дип күрсәтелә. К.П.Берстель җыентыгында Карачүрмә һәм Мөндеш авыллары икесе ике номер белән искә алына. Ләкин халык саны ике авылныкы бергә берләштереп бирелә, аларда барлыгы 880 кеше яшәгән, алар мөселман дине тотканнар. Н.Б.Борһанова мәгълүматларына караганда, Мөндеш авылы халкы күршедәге Өчиле, Югары Бирәзә (Бирәзәбаш), Урта Бирәзә, Зур Бирәзә, Югары Әзәк, Түбән Әзәк, Мөндеш, Югары Мәтәскә, Түбән Мәтәскә, Кәче, Күкчә Бирәзә авыллары белән бергәләшеп июль башларында Күкчә җыены яисә Кыр җыены үткәргәннәр.

Мин яшәгән Татарстан урамы авылның иң озын урамы, анда 84 йорт бар. Йортлар тыгыз булып, кара-каршы итеп авыл зиратыннан Иске Кырлай ягына озын булып сузылган. Үлчәсәң бер чакрым бардыр, озынрак булмаса. Урамның иң иске йорты Саттарова Рәфига апалар йорты, ә иң яңа йорт Җәләлиев Илфат абыйларның йорты, алар анда 2015 нче елда гына яши башладылар. Сираҗиев Фәргать абыйлар йорты урамыбызда гына түгел, авылда иң матур йорт. Урамыбызда яңадан-яңа йортлар төзелсен иде дип телим мин.

*Тарихи-мәдәни истәлекләре һәм танылган шәхесләре*

Урамның нәкъ уртасында 2000 еллар башына кадәр Л.В.Мостаев йорты сакланган. Мәхәллә мәчете имамы Лотфрахман Вәлиәхмәт улы Мостаевның бер катлы агач йорты XX гасыр башында төзелгән.1918 елда йорт хуҗасыннан тартып алынган һәм анда авыл Советы урнашкан.

Мөндеш авылы руханиларыннан тарихта тирән эз калдырган шәхес-имам Фәйзулла Мортазин әл-Мендеши (1850 елда вафат) да безнең урамда яшәгән. Замандашлары тарафыннан “йолдызчы” дип исемләнгән Фәйзулла хәзрәт заманының камил белемле кешесе, зыялысы була. Ул математика фәннәре һәм астрономия өлкәсендә тирән белемнәр үзләштерә, кояш һәм айның тәүлеклек хәрәкәтен исәпләп календарьлар төзи, сәгатьләр һәм астрономик әсбаплар ясый. Бу әйберләр озак еллар дәвамында Ш.Мәрҗәнидә саклана диелә китапларда.

1860 елның 27 октябрендә имамлык вазифалары Вәлиәхмәт Габдрахман улы Мостаевка (туган вакыты-16.08.1838) йөкләнә.1894 елның 21 декабрендә мәхәллә халкы аңа ярдәмче итеп улы Лотфрахман Мостаевны (туган елы-1867) билгели. Л.В.Мостаев мәдрәсә белән җитәкчелек итүне дә үз өстенә ала. Анда 70 ир бала һәм 65 кыз бала укыган (Салихов, Хайретдинов 1895,150-151).

*Көмешче осталар*

Урамның тарихы кызыклы. Ул авыл тарихы белән бергә үрелеп бара дисәң дә була. Безнең авыл урамы кылыч ясаучылар, бакыр-көмеш коючылары белән дан тоткан. Шуларның берсе Гыйбадуллин Сөнгать. Ул 1897 нче елда туган. Аның бертуган энесе Каюм да көмешче булган. Алар бөтен эшне дә бик оста башкарганнар. Каюмга әтисе Яңа Кырлай

авылына өй салып биргән һәм аны башка чыгарган. Ә Сөнгать абый Мөндештә калган. Ул җиздән комганнар, самоварлар ясаган, сәгатьләр, сепараторлар ремонтлаган. Бу һөнәрләрне аңа әтисе өйрәткән. Ул шулай ук кыңгыраулар һәм шөлдерләр дә ясаган. Сөнгать бабай җиз самоварларны никельләп тә куя торган булган. Ул үзе ясаган әйберләрне базарга алып барып саткан.

Бервакыт Сөнгать абыйларга бер рус кешесе, малаем өйләнәсе иде, кыңгырау кирәк дип, гозерләнеп килгән. Бәһасын күпме сорасаң, шуның кадәр бирәм, дигән. Ул рус Сөнгать абыйның кыңгырауга күпме бакыр, цинк, җиз, кургаш һәм көмеш кушып ясаганын карап торган.

Күпмедер вакытлар үткәч, Сөнгать абый базарга кыңгырау сатарга бара һәм ул базарда теге русны күрә. Ул да кыңгырау сатарга килгән була. Сөнгать абый аптырап кала.

“Үзең белгәнне, улым, кешегә өйрәтмә. Аннары синнән дә остаралар,”- дип әйтә иде эти дип, сагынып искә алган улы Мидхәт абый.

Икенче данлыклы көмешче - Фәхретдинов Гафетдин. Ул 1890 нчы елгы. Гафетдин абый көмештән чулпылар, балдаклар, алкалар, беләзекләр ясаган. Аңа көмештән әйберләр бизәнү әйберләре ясатырга күрше-тирә авыллардан да килгәннәр. Ул яңаларын да ясаган, искеләрен ремонтлаган да. Хәтта ул алтыннан да кул көче белән алкалар, йөзекләр ясаган. Гафетдин абый Башкириягә дә барып эшләгән. Үзе ясаган әйберләрне базарга алып барып сата торган булган.

Шәмсетдинов Касыйм һәм аның бертуган абыйсы Мөхәрләм дә данлыклы көмешчеләр булганнар. Алар да чулпылар, йөзекләр, алкалар, беләзекләр, ясаганнар. Үзер әйберләрен базарга алып барып сатканнар.

Хәзерге Әүхәдиев Рафис абыйлар урынында Насыйбуллин Газиз абый белән Майфруз апа яшәгәннәр. Газиз абыйның төп һөнәре - тимерче. Ул Мөндеш МТС ында эшли. Аңа шушы авыл кешеләре һәм тирә-күрше авыллардан комган, самовар кебек әйберләр ясатырга килгәннәр.Ул бик оста булган. Газиз абый тормыш иптәше Майфруз апа белән ике ул (Мансур һәм Рәшит) һәм бер кыз (Рая) тәрбияләп үстерәләр. Газиз абый үлгәч, алар Донбасска күчеп киткәннәр.

*Балта осталары*

Мәчет манарасы утыртып йөрүче балта осталары да булган Мөндештә: Солтангәрәй, Ибраһим, Гаяз һәм Хәйрулла абыйлар. Алар бер бригада булып, кешеләргә өйләр дә салып йөргәннәр. Күрше-тирә авылларга да мәчетләр салганнар. Мөндеш халкы бик һөнәрле булган. Ситдиков Садык, Хәйретдинов Сәләх, Садыйков Закирләр оста чабата ясаганнар. Авыл халкы гел шуларга мөрәҗәгать иткән. Шулай ук, бәби арбасы һәм уфалла арбасы ясап сатучылар да булган. Менә алар: Минңнуллин Хәбибулла, Хәсәнов Фәйзрахман, Бәдриев Гариф. Ә менә Мөхәмәдиев Исхак бәби арбасына бишек тегүче булган.

*Кылыч ясаучылар*

Мөндеш авылы үзенең кылыч бәйләүчеләре белән дан тоткан. Сугыш коралы осталары түгел, ә туку станогының мөһим өлеше ул кылыч. Кылыч ул - киндер һәм җитен тукымалар сугу өчен файдаланыла торган корал.

Оста кылыччыларның берсе -Исхаков Солтангәрәй. Алар гаиләләре белән нечкә әйберләр суга торган сигезле, тугызлы, унлы кылычлар бәйләгәннәр. ”Иртәнге сәгать өчтән торып эшкә тотына идек, көнгә 10 ар кылыч бәйли идек”,- дип искә ала Разыя апа. Ул кылычларны сәүдәгәрләр килеп алып китә торган булганнар. Шулай ук, Ибраһим абзыйлар да данлыклы кылыч бәйләүчеләр булган.

Ясалган кылычны бик ерак җирләргә: Башкортстанга, Сарапул якларына, Түмән өлкәләренә илтеп сату өчен Мөндеш авылыннан аерым сәүдәгәрләр йөреп торган. Халыктан арзан бәягә алып, чит җирдә үзенә күп акча туплаудан баеп, соңыннан кулак булу дәрәҗәсенә ирешкән, Мөндеш халкының җелеген суыручы Гобәй Гыйбадулласын, ә ул чорда анда эшләүче Хәйретдинов Галәү бабай ләгънәт белән искә алып сөйли торган була.

*Пекарня*

Хәзерге Рахматуллин Мансур абыйлар йорты янында пекарня була. Ул 1936-37 нче елларда төзелә. Иң беренче анда Шәйхулла дигән Күкчә кешесе эшләгән. Аннары ул киткәч, Өчиле авылыннан Шәвәли дигән кеше эшләгән. Анда зур ак күмәч пешергәннәр. Халык аны бик яратып алган. Өчиле кешесеннән соң Үрнәктән килеп, Нюра исемле рус хатыны эшләп йөргән.

1952 нче елда Мостафина Суфия апай алты айлык курсларда ипи пешерү серләренә өйрәнеп кайта. 1953 нче елдан пекарняда эшли башлый. Вафина Фәния, Шәйхетдинова Тәскирә, Сираҗиева Галияләр дә эшләгән пекарьняда. Эшне ике сменада оештырганнар. Бар эш тә кул көче белән башкарылган. "Утынны да үзебез кистек, суын да ташыдык. Арыш ипиенә 11 чиләк су, ике капчык он китә иде. Ә күмәчкә 10 чиләк су һәм капчык ярым он кирәк була иде,"- дип искә ала Суфия апа Мостафина. Шул камырдан 110 форма чыккан. 1966 нчы елның башында Мөндеш авылында пекарня бетерелгән. Ул Арчага күчерелгән.

*Сельпо*

Хәзерге Нәбиуллин Наил абыйлар торган урында элек Маһибәдәр апа торган. Башта сельпо шушы Маһибәдәр апа өенең бер өлешендә булган. Аннары яңа сельпо салганнар. Ул бина Язилә апа белән Марзия апа өйләре арасына урнашкан. Анда Ибниев Габдрахман дигән кеше сельпо председателе булып эшләгән. Аның урыныа Күкчә кешесе Габрахманов Фәрит килгән. Сельпо председателе булып Зиннәтуллин Хафиз (Түбән Мәтәскә кешесе), Сабиров Үзбәк, Мальцев Иваннар эшләгән. Ул вакытта бухгалтер булып Шәмсия апа, Фәйрүзә апа эшләгән.

1953 нче елның маенда Мөндеш сельпосына бухгалтер ярдәмчесе булып Җәләлиева Рәхилә апа килә. Ул биредә Шәмсия, Разыя апалар һәм Васил абый белән бергәләп эшләгән. Рәхилә апа 1966 нчы елга кадәр бухгалтер булып эшләвен дәвам иткән.

Разыя апа Мөндеш сельпосына 1959 нче елда килә. Аны склад мөдире итеп куялар. 1966 нчы елда Мөндеш сельпосы Үрнәккә күчерелә. Разыя апа Үрнәккә йөреп эшли. Ул 1971 елда лаеклы ялга чыга.

*Авыл мәктәбе*

Урамыбызның уртасында мәктәп бар. Беренче совет мәктәбе 1917 нче елда ачыла. РТ Милли архивы мәгълүматларыннан күренгәнчә, 1920 нче елның 1 сентябрендә мәктәптә 4 класста 160 бала (78 ир бала, 82 кыз бала) белем алган. 1921 нче елның февраленә укучылар саны 145кә кала. Ачлык вакыты укырга мөмкинлек бирми. Укытучылары дүртәү булган. Казанның Гали мәдрәсәсен тәмамлаган 20 яшьлек Мирза Бәширов мәктәп мөдире булган. Икенче укытучы Сәлих Галиев. Аңа да 20 яшь, мәдрәсә белемле. Икесе дә комсомол булганнар. Өченче укытучы 16 яшьлек, Ахун мәдрәсәсен тәмамлаган Мәхмүт Шәфиев. Дүртенче укытучы Әюпова Сәйдә, 3 класс татар училищесын тәмамлаган, 18 яшьтә. Ул да РКСМ члены булган. Укуэлеккеге мулла өендәоештырылган. 1926 нчы елны Мөндеш авылында башлангыч мәктәп мәчет бинасында оештырылган. Мәктәптә Балтач ягыннан килгән Әминә исемле укытучы (фамилиясен хәтерләүче юк) укыткан. Көндезләрен укыткан, ә кичләрен кызларны кул эшләренә өйрәткән.

1934 нче елны мәктәпкә Субаш - Аты мәктәбеннән яшь укытучы Марзия апа Сөләйманова килә. Ул 30 елдан артык укыта. 1951 -1952 нче уку елында Мөндеш авылында җидееллык мәктәп төзелә. Ә мәчетне сүтәләр. Бу мәктәпнең беренче директоры Сәйфетдинов Каюм Шиһап улы була. Аннан соң директор булып Вәлишин Рәүф, Шакиров Госман, Камалетдинова Гөлчирә, Мөхәммәтҗанов Илдуслар эшлиләр.

1967 нче елдан директор булып Салихов Әнвәр Салих улы эшли башлый. 1974 нче елда Мөндеш сигезьеллык мәктәбе Иске Кырлай авылына күчә.

Мөндеш мәктәбендә эшләгән укытучылар:ХәсәноваРәшидә - директор урынбасары, югары белемле математик; Шәрәфиева Рәйсә – профсоюз комитеты председателе, татар теле укытучысы, Салихова Әнисә – тарих укытучысы, Сабирова Нажия – рус теле укытучысы, Хәйруллина Мәдинә – математика, физика укытучысы, Вагыйзова Люция - немец теле укытучысы, Гарипов Мәгъфүр – физкультура һәм хезмәт укытучысы, Хөсәенова Ания, Нуриева Асия, Рахимова Фидания, Хәйретдинова Әлфинур, Хөсәенова Рәйханә, Низамиева

Әминәләр – яшь укытучылар булалар. Башлангыч классларны Сөләйманова Марзия апа һәм Шәйхелисламова Рәхимә апалар укыта.

1974 нче елдан Мөндеш авылында мәктәп башлангыч мәктәп булып кала.

1988 нче елда Мөндеш башлангыч мәктәбе яңа салынган бинага күчә. Аның мөдире итеп Шәйхелисламова Рәхимә Шәйхелислам кызы билгеләнә. Ә 1989 нчы елның сентябрь аенда балалар бакчасы белән башлангыч мәктәпне комплекс итеп үзгәртәләр. Комплекс директоры итеп Мөхәрләмова Рима Галип кызы билгеләнә. Бүгенге көндә башлангыч класста 22 бала укый, ә балалар бакчасына 50 бала йөри.

*Йомгаклау*

Туган авылымның мин яшәгән Татарстан урамы көннән-көн матурлана, яңара, үсә бара. 2001 нче елда урамга ямь биреп мәчет төзелде. 2005 нче елда урамга асфальт җәелде. 2013 нче елда фельдшер-акушерлык пункты ачылды. 2015 нче елда иске башлангыч мәктәп һәм балалар бакчасы урынына 50 урынлык заманча бакча-мәктәп ачылды. Авыл халкы тырышлыгы белән балалар өчен шугалак та ясалды быел. Киләсе елга, авария хәленә килгән клуб урынына яңасы төзелер дигән өмет тә бар.

Авылым урамы тарихы белән танышу миңа бик тә ошады. Бу әле авылым тарихын өйрәнүнең бер өлкәсе генә, алга таба әле укытучыбыз белән берлектә авылымның башка кызыклы өлкәләрен дә тикшерербез, ачарбыз дип уйлыйм .

“Үткәне барның, киләчәге бар” ди безнең халык. Әгәр без бүгенге көндә өлкәннәр хәтерендә сакланган бай тарихыбызны җыеп кала алмасак, тарихыбызның бер өлешен югалтырбыз. Туган урамымның бер өлеш тарихын яздым, әле язылмый калган факт-вакыйгалар бик күп. Киләчәктә, урам тарихын тирәнтенрәк өйрәнергә мөмкин булыр дип уйлыйм. Минемчә, тарих, һичшиксез, тиешенчә өйрәнелергә, язылырга һәм киләчәк буыннарга кителмәгән, бөтен килеш тапшырылырга тиеш. Мин туган авылымны, үзем яшәгән урамымны яратам!

*Кулланылган әдәбият исемлеге.*


1. Фирдәүс Гарипова. Авыллар һәм калалар тарихыннан.—Казан,1997 ел.
2. Татар халкының тарихи һәм мәдәни һәйкәлләре.Казан, 1995 ел, “Фест”.
3. Бөек Тукай ватаны син, Арча. Казан, 2007.
4. Арча төбәге тарихы. Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1996.
5. Арча районы Түбән Мәтәскә урта мәктәбе музее материаллары.
6. Мөндеш авылында яшәүче Зиннатуллин Камил Шамил улы истәлекләре.


## ӘФГАН СУГЫШЫНДА ЯКТАШЛАРЫБЫЗ (1979-1989 ЕЛЛАР)


*Зиннатуллина Дина Камиловна, ученица 8 класса*
*Научный руководитель – Закирова Лилия Ахатовна*
*МБОУ "Нижнеметескинская СОШ"*
*Арского муниципального района РТ*


Әфганчылар турында күп китаплар язылган, кинолар төшерелгән. Ел саен 15 февраль көнне, Әфган җиреннән чикләнгән совет гаскәрләре чыгарылып беткән көнне, алар белән очрашулар үткәрелә. Тикшерү эшемнең **проблемасы** булып туган ягым Арча районында яшәүче әфганчылар турында материал туплау, алар турында күбрәк белү тора.

“Үлгәннәрнең каберен, исәннәрнең кадерен бел”, дигән халык мәкален тикшерү эшемнең **максаты** итеп алдым. Еллар уза, әфганчылар да олыгая, кайберләре сугыш яраларыннан яисә башка сәбәпләр белән вафат була.

Тикшерү эшем барышында яшьтәшләремнән әфган сугышы, әфганчы якташларыбыз турында сораштым. Әфган сугышының ни сәбәпле булганын барысы да белеп үк

бетермәсәләр дә, алар әфганчы якташларым турында беләләр. “Арча хәбәрләре” газетасы материаллары белән таныштым. Татарстан әфганчыларына багышланган китапларны барладым. Мәктәп музее материаллары белән таныштым. Шулай ук, интернет материалларын карап чыктым. Дөрес, татар телендә Әфганстан сугышы турында тулы материал тапмадым. Үзем укыган урта мәктәпкә килеп укучылар белән авылдаш-әфганчыларның фотоларын җыйдык. Әфганчы этием үз истәлекләре белән уртаклашты.

*Төп өлеш. Әфган сугышында (1979-1989 еллар) якташларыбыз*

*Әфганстан– Урта көнчыгышта урнашкан дәүләт*

Дөньяның иң фәкыйр илләренең берсе. Соңгы 30 ел дәвамында (1978 елдан башлап) илдә гражданнар сугышы бара. Гомуми мәйданы 647 мең квадрат километр булган илдә әле 1982 ел үрендә дә автомобиль юллары нибары 18 мең чакрым. Илдә тимер юл бөтенләй юк.16 миллион халыкның зур күпчелеге ярымкүчмә тормыш алып бара.Төп шөгель - терлекчелек. Күпчелек халкы –көтүче. Кеше хакын тиеннәр белән генә бәялиләр. Бер феодал икенчесенә батракларны ике капчык борчак, я булмаса бер капчык дөгегә күз дә йоммыйча сата. Нигездә феодализм чорында яшәгән дәүләткә капиталистик мөнәсәбәт кереп кенә бара.

Менә шушы илдә 1978елның 27 апрелендә, Брежнев заманы идеологлары тәкърарлавынча, милли-демократик революция, ә чынында исә законлы властьне хәрби көчләр ярдәмендә бәреп төшерү була. Габдел Кадыйр җитәкләгән хәрбиләр призедент кәнәфиенә халык партиясенең генераль секретаре Нур Мөхәммәт Тәрәкыйны утырта. Тәрәкый икенче көнне үк илне Әфганстан Демократик Республикасы дип, ә үзен Революцион Совет рәисе, Югары Оборона Советы рәисе, дәүләтнең баш министры дип игьлан итә, шулай бар властьне үз кулына ала.Тәрәкый хөкүмәте белән СССР арасында дуслык җепләре урнаштырыла, матди, техник, экономик ярдәм күрсәтелә, Әфганстандагы революцион гаскәр составына совет хәрби киңәшчеләре җибәрелә. Ике ил дус-туган кебек яши. Ләкин аның тантанасы озакка бармый. 1979елның февралендә Герат каласында революцион дивизия Тәрәкый диктатурасына каршы баш күтәрә. Фетнәчеләрне Әмин җитәкли. Сентябрьдә Әмин кушуы буенча Тәрәккый үтерелә. Әмин призедент кәнәфиенә утыра. Ил ике лагерьгә аерыла. Әфганстанда гражданнар сугышы канат җәя.

*Чикләнгән совет гаскәрләре Әфганстанда*

1979 елның 12 декабрендә Политбюро утырышында совет чикләнгән гаскәрләрен әфган җиренә кертү карары чыгарыла. Декабрь ахырына бу карар тормышка ашырыла башлый.

Әмин хөкүмәтен бәреп төшереп, революцион Кармаль хөкүмәтен яклау бурычы гына куелса да, совет гаскәрләре ил эчендәге сугыш хәрәкәтләренә катнашып китәргә мәҗбүр була. Ә сугышлар корбаннарсыз булмый. 1980 елда Әфганстан җирендә -1500гә, 1981дә - 1300гә, 1982дә 2000гә якын совет сугышчысы вафат була. Яралыларның саны 10000гә җитә.1983 елда – 1500гә, 1984тә 2400гә якын совет сугышчысы туган туфрагына кәфенлеккә төренеп кайтты.

1985 елның апрелендә Ватаныбыз өстендә сафландыргыч, аяз җилләр исте. Фәкать 1988 нче елның 15 нче маенда гына совет гаскәрләре сугыштан чыгарыла башлады. 1989 елның 15 февралендә соңгы совет солдаты Әфганстанның чиген атлап чыкты. Бу сугыш 15 меңгә якын кургаш табут, 36мең яралы, 312 хәбәрсез югалган солдат рәвешендә әйләнеп кайтты. Әфган мәшхәрен безнең илнең 546255 кешесе үтте, шуларның 6669е гарипләнде, ә 49985е яраланды. 312се хәбәрсез югалды, 18е чит илләрдә калды. 13833е үлде. Әфган сугышында югалтулар: руслардан 6888 кеше, украиннардан 2378 кеше, үзбәкләрдән 1066 кеше, белоруслардан 613 кеше, татарлардан 442 кеше, казахлардан 362 кеше, чувашлардан 125 кеше, кыргызлардан 102 кеше.

*Якташларыбыз – Арчалылар Әфганстан җирендә*

1979-1989 нчы еллардагы Әфган сугышында Татарстаннан 10 меңләп ир-егет катнашты. Шуларның 132 се арчалылар. Өч якташыбыз үзләренең сугышчан бурычларын үтәгәндә һәлак булдылар. Аларның исемнәре: Әһлиуллин Васыйл Габдуллович. 1966 елда

Пешәнгәрдә туган. Танкист- механик. 1985елда вафат. Кызыл Йолдыз ордены иясе. Бикбаев Фәнис Мөхәммәт улы.1961елда Поч-Поник авылында туа. Армиядә өлкән разведчик. Үлгәч, ”Батырлык өчен” медале бирелә. Лотфуллин Марат Әлтаф улы. 1969елда Арчада туган. Танкист. 1987 елда вафат. Кызыл Йолдыз ордены иясе. 19 әфганчыбыз сугыштан соң арабыздан китте.

Арча районында сугышчы-әфганчылар һәм башка локаль сугышларда катнашучыларның “Сугышчан туганлык” җәмәгать оешмасы төзелгән. Аны подполковник Сергей Баһаветдинов җитәкли. Ел дәвамында социаль яклау, хәрби-патриотик тәрбия өлкәсендә даими эш алып барыла. Әфганчылар турында мәгълүматлар туплана.

Районыбызда әфган сугышында катнашучыларның барысына да “Рәхмәтле Әфган халкыннан” (“От благодарного Афганского народа”) медале һәм “Сугышчы-интернационалистка» («Воину-интернацииналисту») билгесе бирелгән. Шулай ук, СССРның, РФнең дәүләт бүләкләре белән бүләкләнүчеләр дә байтак.Баһаветдинов Сергей Лимусович “Хәрби хезмәтләре өчен” ордены белән бүләкләнә. 7 якташыбыз “Кызыл Йолдыз” ордены белән бүләкләнгән: Әһлиуллин Васыйл Габдуллович, Әхмәтгалиев Гарифулла Нургалиевич, Баһаветдинов Сергей Лимусович, Галимҗанов Раил Мөхәммәтович, Казаков Ренат Галиевич, Лотфуллин Марат Әлтафович, Шәйхетдинов Разил Низаметдинович. “Батырлык өчен” медале белән бүләкләнүчеләр унбиш: Әхмәтгалиев Гарифулла Нургалиевич,Баһаветдинов Сергей Лимусович, Шәйхетдинов Разил Низаметдинович, Апайчев Александр Петрович, Бикбаев Фәнис Мөхәммәтович, Вәлиев Вәис Вәдүтович, Гайнетдинов Илгиз Раифович, Галипов Рафис Хәнифович, Мәхәммәтҗанов Айрат Нәкыйпович, Рәхиев Радик Минханович, Сабиров Данаил Рамазанович, Сәмигуллин Рафил Габделбәрович, Шакирҗанов Дамир Закиҗанович, Шафигуллин Рафаэль Нургалиевич, Хөснетдинов Әмир Дамирович. “Сугышчан хезмәтләре өчен” медале ияләре: Абдуллин Фоат Минзиевич, Вәлиуллин Радик Хатыймович, Галипов Рафис Хәнифович, Галиуллин Фәрит Әхмәтович, Закиров Салихҗан Мәгъсүмович, Ишбаев Рәдиф Рәшитович, Кислов Сергей Викторович, Мусин Рафаэль Гомәрович, Садыйков Фәнис Турисович, Шакирҗанов Дамир Закиҗанович, Шәйдуллин Вабил Вәдүтович.

*Авылдашларыбызның батыр хәрби хезмәте*

Күрше Иске Төрнәле авылындадә әфган сугышын кичкәннәр берничә. Миннеханов Әнис Нурмый улы, 1962 елда туган, Төрнәледә яши. 1980-1982 елларда разведчик булып хезмәт итә. Укучылар белән очрашуларга еш килә. “Әфганстан җиренә барып, хезмәт иткән җирләрне кабат күрәсе килә,”- ди ул. Хәбибуллин Илнур Гыйззәт улы, 1962 елгы, 1980-1982 елларда шофер булып хезмәт итә. Тимашев Фәнис Илгиз улы, 1965 елгы. Төрнәледә яши. 1983-1985 елларда пулеметчы булып хезмәт итә. Фәнис абыйның армиядән кайткач, читтән торып университетның журналистика факультетын тәмамлый. “Арча хәбәрләре” газетасында, “Арча” радиосында эшли. Соңрак Казанбаш җирлеге рәисе вазифаларын башкара. Шигырьләр яза. Иҗатының бер өлеше әфган сугышы, иптәшләрен югалту сагышына багышланган.

Күршедәге Алга-Көек авылыннан әфганчы-сугышчылар бишәү. Надршин Идрис Юныс улы 1961 елда Көек авылында туган. 1979-1981 елларда Бахрамда десантник булып хезмәт итә. Шәйдуллин Вабил Вәдүт улы 1962 елгы, Көек авылында яши. 1980-1982 елларда меноментчы була. Нурязданов Ризван Рамазан улы. 1962елда Көектә туа. Хәзерге вакытта Яр Чаллыда яши. 1980-1982 елларда Шиндантта хезмәт итә. БТР йөртәүче була. Төхфәтуллин Ринат Рәис улы. 1965 елгы. Хәзер вафат.1983-1985 елларда артеллирист булып хезмәт итә. Хөсәенов Илдус Тимершәех улы Көектә яши. 1988-1989 елларда разведчик була.

Мин укыган Түбән Мәтәскә авылыннан әфган сугышында 1961 елда туган Галиуллин Зиннур Хәлил улы катнаша. Хәрби хезмәттән кайткач, Мәскәүгә китә. Ике ул үстерә. Озак еллар метро төзелешендә эшли. Хәзер Арчада яши.

Классташым Илнурның әтисе, Казиле авылыннан Сираҗиев Илгизәр абый сугышта катнашуы турында бөтенләй сөйләргә яратмый. Ул 1984-1986 елларда хәрби хезмәттә була, Шинтдантта БТРда хезмәт итә.

Югары Мәтәскә авылы егете Шәкүров Илдар Исмәгыйль улы хәрби хезмәткә 1984 елда китә. Өч ай дәвамында Әрмәнстанда өйрәнүләрдә була. Аннан Әфганстан. Шиндат, Кандагар шәһәрләрендә БТРда хезмәт итә. Армиядән кайкач, Арча юл идарәсенә эшкә урнаша. Гаиләсе бар. Ике бала үстерәләр.

Камалиев Фәргать Әсхәдулла улы да сугышчы-интернационалист. Аз сүзле. Сугыш турында искә алырга яратмый. Армиягә кадәр дә, хәзер дә шофер. Тормыш иптәше Фирдания ханым белән ике кыз үстерделәр.

*Әфганчы әтиебез истәлекләре*

Эзләнү эшемә этәргеч бирүче кеше минем әти, Рафиков Фидәрис Хәмит улы. Ул 1969 нчы елның 5 августында Теләче районы Яңа Җөри авылында гаиләдә өченче бала булып дөньяга килә. Урта белем алгач, 1987 нче елның 15 нче ноябрендә армия сафларына китә. Хезмәт итүе Төрекмәнстанның Тахта – Базар шәһәреннән башлана. Шунда өч ай хәрби укуларда була.

1988 нче елның март аенда Әфганстанга кертәләр. Анда миномет батареясында шофёр булып хезмәт итә. Төрле сугышчан хәрәкәтләрдә катнаша. 1989 нчы елның 13 нче февралендә Әфганстаннан чыгаралар. Ә 15 нче февральдә соңгы совет солдаты әфган җиреннән чыга. Ноябрьдә хезмәтен бетереп кайта. Үзен аямыйча хәрби бурычын үтәгән өчен медальләр белән бүләкләнә. Беренче медале – “Воину-интернационалисту от благодарного афганского народа», икенчесе - «За отличие в охране государственной границы СССР». 1989 нчы елдаСССР КГБ коллегиясе кул сәгате белән дә бүләкли аны. Әфганистаннан чыгуга 25 ел уңаеннан 2014 нче елда медаль белән бүләкләнә. Әфганистанда булганын ул сөйләргә яратмый, нык дулкынлана.

*Йомгаклау*

Мәктәбебездә 15нче февраль — Әфган җиреннән соңгы совет солдаты чыгарылган көн һәр ел зурлап искә алына. Быел да якташ әфганчы-интернационалист ир-егетләребез хөрмәтенә тантаналы искә алу чарасы узды.Әфганстан иле, халкының тормышы, сугышта күргәннәре турында сөйләделәр. “Ватанны саклау - һәркемнең изге бурычы, сез дә бу бурычны лаеклы үтәрсез дип ышанам”, - дип тәмамлады кичәне оештыручы тормыш иминлеге укытучыбыз Фазылҗанов Гамир Габделхак улы.Бирердә катнашкан мәктәп укучылары тарихның шомлы елларын белеп, «Сугыш» дигән сүзнең ачы мәгънәсен аңлап, сабак кына түгел, үзләренә олы рухи байлык та алдылар.

Эзләнү эшемнең төп **нәтиҗәләре** дип түбәндәгеләрне саныйм:

1. 1979-1989 нчы еллардагы Әфган сугышында 132 арчалы катнашты. Өч якташыбыз үзләренең сугышчан бурычларын үтәгәндә һәлак булдылар. 22 сугыштан соң арабыздан китте. Дистәләгән кеше орден-медальләргә лаек булган.

2. Хакыйкать ничек кенә ачы булмасын, аны таный белергә дә кирәк. Безнең үз тарихыбызны онытырга хакыбыз юк!

Нәтиҗәләрдән чыгып алга **бурычлар** куйдым**:** якташ-әфганчылар турында истәлекләр туплауны дәвам итү, әфганчы якташларыбызны һәрвакыт очрашуларга чакыру, алардан туган илебезне яратырга һәм сакларга өйрәнү; “кайнар нокталарда” хезмәт иткән башка якташларыбызны барлау.

Әфганчы-интернационалистлар — безнең горурлыгыбыз һәм аларның батырлыгы яшь буынга олы үрнәк өлгесе!

*Кулланылган әдәбият:*


1. “Әфган кызалаклары”, Вахит Имамов, Татарстан китап нәшрияты, 1991.
2. “771 аршин җир”, Әхәт Гаффар, Татарстан китап нәшрияты, 1991.
3. “Арча хәбәрләре” газетасы, 2007, 2009, 2012
4. http://ru.wikipedia.org/wiki/
5. http://ru.wikipedia.org/wiki/%D0%90%D1%84%D0%B3%D0%B0%D0%BD%D1%81%D0%BA%D0%B0%D1%8F_%D0%B2%D0%BE%D0%B9%D0%BD%D0%B0_%281979%E2%80%941989%29

6. http://napalm-po-ytry.narod.ru/afganskaya_voina_/
7. http://arskmedia.com/2012/03/02/pamyati-afgancev/#more-3107
8. http://pv-afghan.ucoz.ru/index/0-59

## АРБАШ - КЕЧКЕНӘ ВАТАНЫМ

*Исхакова Нафиса Фаниловна, ученица 5 класса*
*Научный руководитель – Гатауллина Лилия Фоатовна*
*МБОУ КСШ №3 Кукморского муниципального района РТ*

*«Яшәр өчен бетмәс көч алырга*
*Олысына һәм дә кечегә, -*
*Мәхәббәтле, ямьле, мәрхәмәтле*
*Туган ягы кирәк кешегә.»*

*Фәнис Яруллин*

Туган җир…Туган авыл...

Йөрәккә нинди якын һәм кадерле бу сүзләр. Безнең һәрберебезнең газиз туган йорты, нигезебез урнашкан кадерле туган авыл бар. Һәр авылның үзенә генә хас кабатланмас, истә кала торган урыннары күп. Сокланып туймаслык тугайлар,челтерәп ага торган йөгерек чишмә буйлары, җикән камыш белән капланган сазлыклар, балыклы күлләр куе әрәмәләр белән уратылган елга үзәннәре, туган ягыбызның кырлары, басулары, шаулап торган урманнары күңелләргә рәхәтлек биреп, туган туфракка мәхәббәт тәрбияли. Кая гына барсак та, нинди генә магур урыннарны күреп соклансак та, туган төбәгебезнең гүзәллеген берни дә алыштыра алмый. Туган ягыбызның һәр сукмагы, һәр агачы, һәр авылы аның барча кешеләре күңелгә ифрат якын. Тәпиләп киткән, беренче тапкыр әттә-әннә дип әйтергә өйрәнгән вакытта ук күңел түренә туган телебез Аша кереп утырган ул кадерле урыннар…

Авыл атамалары безнең борынгы тарихыбызны, данлы үткәнебезне көзгедәге кебек чагылдыралар. Бер атама да юкка гына бирелмәгән. Аларның нигезендә атама кую өчен берәр сәбәп ята. Бер ишеләре этнонимга, икенчеләре тарихи вакыйгаларга, өченчеләре гадәт-йола кануннарына һәм башка үзенчәлекләргә нисбәтле рәвештә бирелә.

Авыллар, авыллар… Аларда безнең үткән, тарихыбызның бер өлеше, халыкның моңы, кайгысы, шатлыгы, куанычлары һәм сагышы. Аларның берләре бик борынгы, икенчеләре шактый соң барлыкка килгән. һәрберсенең үз исеме, тарихы , үз даирәсе, үз мөхите, үзенең данлыклы кешеләре бар. Шуның өстенә авыллар милләтебезгә, халкыбызга җиң сызганып хезмәт итүче кадрлар бирә торган изге урыннар. Авыллар гөрләтеп яшәсә, милләт, халык яшәр, үсәр һәм көчәер.

Һәр кеше өчен үзенең туган ягы кадерле. Миңа да шулай. Балтачыбыздан да матуррак, якынрак җир юк кебек. Бигрәк тә туган авылым Арбаш кадерле. Җир йөзендәге башка кешеләр өчен дә иң газиз урын – ул туган авылдыр. Шуңа күрә без аның тарихын яхшы белергә, табигатен сакларга, кешеләре белән горурланырга тиеш.

Һәрбер төбәкнең үзенчәлекле тарихы, күренекле кешеләре бар. Балтачыбыз да бай тарихлы районнарның берсе. Район үзәге булган Балтач авылына 1396 нчы елда нигез салынган. Район аша данлыклы Себер тракты уза. Сәяхәт вакытында А.Н.Радищев, Балтач аркылы үтеп, үзенең елъязмаларында Яңгул, Кариле, Арбаш авыллары, халкыбыз турында җылы сүзләр яза.

Безнең районда ике гасырлы тарихы булган Түнтәр, бөек Тукаебызның әнисе җирләнгән Сосна Пучинкәсе, Тумашевларның нәсел чылбыры барып тоташкан Нөнәгәр, “Халыклар дуслыгы” музее урнашкан Чепья, М.Фәйзи яшәп алган Шода, “Себер юлы

тарихы” һәм герой шагыйрь Муса Җәлил музейлары булган Карадуган һәм башка бик күп данлыклы авыллар бар.

Татар халкын данлыклы иткән Тукай премиясе лауреаты, язучы Ибраһим Сәләхов (Чутай), шагыйрьләр Хәбра Рахман (Яңгул), Сөләйман Мөлеков (Пыжмара), эстраданың күренекле җырчысы Альберт Асадуллин (Чапшар), Республиканың атказанган артистлары Римма Ибраһимова (Түбән Кенә), Рәшит Мостафин (Сосна), беренче хатын-кыз режиссер Кәшифә Тумашева (Нөнәгәр), Татарстанның атказанган артисты Җәвәһирә Сәләхова (Таузар), беренче татар адмиралы Марс Искәндәров (Әтнә), галим Гыйният Халиуллин (Арбор), академик Әхмәт Мазһаров (Сосна), шагыйрь Гарифҗан Мөхәммәтшин (Арбор) һәм башкаларның туган җире булган Балтач районында тууым белән мин чиксез горурланам

Мин – Балтач районының Арбаш авылы кызы. Бабаларым килеп төпләнгән, әтием үскән кечкенә генә авылым турында мин күбрәк белергә тиеш. Зур, мәртәбәле, иксез-чиксез Ватан кечкенә генә авылымнан башлана бит. Үземнең туган авылымны районыбыздагы калган данлыклы авыллар белән бер рәттә күрергә телим мин. Кечкенә генә авыл түгел, ә зур тарихлы, китапларга язарлык матур кешеләре булган авыл итеп танытасым килә.

Бу эшемдә мин үз алдыма авылымның беркем тарафыннан да өйрәнелмәгән тарихын барлауны максат итеп куйдым. Максатыма ирешү өчен, түбәндәге бурычларны билгеләдем:

1. Туган авылымның тарихын өйрәнергә.
2. Авылымнын тарихи истәлекле урыннарын өйрәнергә.
3. Арбаш диеп «янып» йөрүче авылдашларымны барларга.
4. Башка кешеләрдә авылыбыз белән горурлану хисе тудырырга.

Максатка ирешер өчен, музей документлары белән таныштым, китаплардан, интернеттан мәгълүмат алдым, фотолар тупладым, авылыбыздагы өлкән кешеләр белән очраштым. Авылымның, чыннан да, бай тарихлы булуына һәм бу тарихны тудыручы Кешеләре булуына инандым.

*Төп өлеш. I бүлек.* Арбашның кыскача тарихы.

Арбаш авылы Татарстан Республикасының Балтач районында, Шушма елгасының уң як кушылдыгы булган Шерә елгасы буена урнашан. Язма чыганакларда Арбаш авылы XVII гасырның урталарында ук барлыкка килгән булуы әйтелә.

Халык телендә йөргән риваятьләргә караганда, Таузар авылыннан Бәшир исемле кеше югалган атын эзләгәндә шушы урынга килеп чыга һәм биредә төпләнеп кала. XVIII гасырга караган документларда ул ике авыл исеме белән йөри: Арбаш-Ширә (русча чыганакларда Арбаш-Шира, авыл Шерә елгасы буенда урнашкан) һәм Арбаш-Бәшир (Арбаш-Поширь).

Авыл яныннан атаклы Себер юлы узган. Арча районы Күлтәс авылы читеннән безнең Арбаш, Карадуган авылларына таба, урман аша сузылган Себер тракты калдыклары барлыгын күпләр белмидер, мөгаен. Салынган еллары патшабикә Екатерина II заманына туры килгәнлектән, аны «Әби патша юлы» («Екатеринский почтовый тракт») дип атап йөрткәннәр. Бүген биредә тынлык. Ә заманында бу юлда ям чапкан (яки «почта чапкан») атларның кыңгырау чыңнары, Себергә сөрелгән каторжаннарның богау тавышлары яңгыраган. Шуннан сәүдәгәрләр мал ташыган, А.Н.Радищев, П.П.Семёнов-Тян-Шанский, Ф.Достоевский, Ш.Мәрҗани, М.Фәйзи кебек зыялылар узган.

Арбашта элек – электән уңган халык яшәгән. Арбаш – Бәшир һәм Арбаш – Шерә авылы кешеләренең скорняклык (мех эшкәртү) белән шөгыльләнүе билгеле. И. А. Износков “Список населенных мест Казанского уезда с кратким описанием” китабында скорняклык белән шөгыльләнүләре аркасында Арбаш халкы бай яши дип бәяләгән.

Авылыбыз абыстае Илфира апа Фатыйхова сөйләвенә караганда, бу чорда авыл байлары Оренбург ягыннан йомран тиресе кайтартып, шуны хуҗалыкларга таратып эшкәрттергәннәр. Бу эш шактый авыр һәм пычрак эш булган. Ләкин халыкка өстәмә керем китергән. Тире эшкәртү белән авыл халкы игенчелектән тыш вакытта шөгыльләнгән. Б. Зыятдинов “Себер юлы буйлап” китабында Арбашта 1926 елда ук мех эшкәртү артеле булганлыгы турында яза.Соңрак ул “Кызыл мехче” артеле дип искә алына. Бөек Ватан

сугышы елларында артель фронт өчен телогрейкалар, мех аяк киемнәре, көрәк чехоллары, фолдат гимнастеркалары теккән. Ул елларда эшнең ике смена итеп оештырылуы да билгеле. Тик ниндидер сәбәпләр аркасында артель эшен дәвам итә алмый һәм юкка чыга. Бүген инде Арбашның атаклы тегүчеләре дә, бүрекчеләре дә, мехчылары да юк

II бүлек. Авылымның табигый истәлекле урыннары

Кем булуыңны белү өчен туган ягыңны тарихи яктан гына өйрәнү җитми, ә географик яктан өйрәнү дә зур әһәмияткә ия. шул максатны истә тотып, мин үз авылымның табигый истәлекле урыннарын, аларның аталу тарихларын бик кызыксынып өйрәндем.

Кемнеңдер туган авылы тау астына урнашкан, ә безнең арбаш тау башында тора. авылымның табигате чишмә - урманнарга, тау һәм елгаларга бик бай. аларның авылыбыз кешеләре өчен генә билгеле үз тарихы, үз атамалары бар.

**Атау** – арбаш авылының ике елга арасындагы ярым атау өлеше. аксакаллар сүзенә караганда арбашның беренче мәчете шул атау өлешенә салынган булган. анда элек йортлар да шактый булган. бүгенге көндә бер йорт та юк.

Тау итәгендә тешләрне камаштырырлык салкын, тәмле сулы ике чишмә бар – **Сирай һәм Әюп чишмәләре**. чишмәләргә аларны карап чистартып торган, улакларын алыштырган, тирә-ягындагы чүп – үләннәрен чистарткан кешеләр исеме бирелгән

Сирай чисмәсенә бүгенге көндә дә тирә-як күршеләр суга төшә. Һәр җәй саен чишмәнең тирә ягын чистартып, кош – кортлар өчен бөя ясап куялар. Җәй буе шушы бөядә каз – үрдәкләр үзләренең бәбкәләрен йөзәргә өйрәтә.

**Арбаш елгасы** – авылның аргы як һәм атау дигән өлешләре арасыннан агып, Шерәгә кушыла торган елга. Елга ике якны тоташтыргангады авыл исемен биргәннәр. Ә Шерә исеменең килеп чыгышын тәгаен генә хәтерләүчеләр табылмады.

**Тавыклы** - Арбаш авылының бирге ягы белән атау арасындагы елга. Бу елганың суы шул тикле сай булган, аны хәтта тавыклар да ерып чыга алган, исеме дә шуннан килеп чыккан.

**Тәкәрлек елгасы** – исеменә караганда, элек анда тәкәрлек дигән кошлар яшәгән булырга тиеш дип фаразлыйлар.

**Нарат капка елгасы** – бу елгага юл ике зур нарат арасыннан үткән булган. 1984 елда монда карьер ясыйлар. Бу карьер бүгенге көндә дә эшли.

**Барак елгасы** – бу елгада Бөек Ватан сугышы вакытында кызылармеецлар бараклар төзеп шунда яшәгәннәр. Моны раслаучы табылдыклар да булган. Бу елга турында мәгълүматны миңа Себер тракты тарихы музее хезмәткәрләре бирде.

**Каланча** – Арбаш басуының түрендә элек каланча булган. Шул җирне әле бүген дә каланча басуы дип йөртәләр.

**Ике катлы урман** – Арбаш басуының түрендә, Себер юлының ике ягы да урман булган өлеше.

**Бер катлы урман** – Урман Себер юлының бер ягында гына урнашкан өлеш.

Урман, елга һәм тауларның аталу тарихын өйрәнеп, мин түбәндәге нәтиҗәгә килдем: бу атамалар безгә борынгы әби-бабаларыбызның тормыш-көнкүреше, һөнәрләре, гореф-гадәтләре, тарихы, теле, төбәкнең табигате, географик үзенчәлекләре һәм башкалар турында мөһим мәгълүмат бирәләр. Һәрбер атама – үзенең килеп чыгышы, мәгънәсе белән тарихның хәбәрчесе икән.

**III бүлек. Авылымның зурлыгы – кешеләрендә**

Авылларның иң зур байлыгы - аның халкы. Безнең авылда да хөрмәткә лаек кешеләр күп яшәгән һәм яши.

Мин Арбаш авылы өчен янып-көеп яшәгән, аны үстерү, таныту өчен күп эшләр башкарган кешеләрнең берсе –Фидәил абый Хәйруллин турында язмакчы булам.

Хәйруллин Фидәил Исрафил улы 1963 нче елда, Арбаш авылында, гади колхозчы гаиләсендә туа. 1981 елда Карадуган урта мәктәбен,1986 елад Авыл хуҗалыгы институтын тәмамлый. Гомер буе туган колхозында агроном-бригадир булып эшли. Ике ул өч кыз үстерә.

Алты балалы ишле гаиләдә иң олы ул, әти-әнинең терәге була ул. Мал-туар асрау, аларга азык әзерләү, йорт арасында булышу аның җилкәсенә төшә. “Энекәшләрне тәрбияләүгә дә шактый өлешем кергәндер”, - дип искә ала ул үзенең бала чагын.

Мәктәптә укыган чагында ук бик актив була: спорт белән шөгыльләнә, хоккей уйный. 10 сыйныфта укыгында Татарстан Республикасы чемпионы дәрәҗәсенә кадәр күтәрелә. Үзешчән сәнгатьтә актив катнаша: җырлый, тальянда уйный, спектакльләр... “Алтынчы сыйныфта укыганда әти миңа баян алып бирде, шуннан бирле баяннан аерылган юк”, - ди ул.

Буген тынгысыз җанлы Фидәил абый туган авылы Арбаш өчен “янып” йөри. Авыл җыеннары, Сабантуйлары оештыра. Шигырьләр, җырлар яза. Шигырьләре күңелгә үтеп керә, чөнки аларда туган авылын ярату, зурлау чагыла.

***Йомгаклау. Зур тарихлы кечкенә Арбашым***

Без туган авылыбызны бик-бик яратабыз. Әйтеп бетерә алмаслык матурлыкны, серлелекне сеңдергән бит ул безнең Арбаш авылы. Ул үзенең иленә батыр, бөркет кебек көчле ир-егетләр, берсеннән-берсе матур, карлыгач сыман чибәр кызлар үстергән.

Безнең авыллар тарихы Себер юлы белән тыгыз бәйләнгән, дөресрәге, аны шуннан башка аңлау да кыен булыр иде. Авыл тарихы Себер юлы белән бәйләнештә өйрәнелә

Эшебездә куйган максатка ирештек дип уйлыйм. Авылыбыз турында шактый күп белешмә алдык. Башкалар сокланырлык матур якларын: данлыклы, эшчән кешеләрен, гүзәл эшләрен күрсәтергә тырыштык. Еллар үткән саен шактый сандагы авылларның беткәнлеген беләбез. Ләкин безнең авылыбыз яшәячәк әле!

*Кулланылган әдәбият:*


1. Бакый Зыятдинов Себер юлы серләре. Казан, 1999.
2. Бакый Зытдинов Себер юлы буйлап: Карадуган, Арбаш авыллары тарихыннан сәхифәләр, Казан, “Идел-Пресс”, 2010.
3. http://beznenmiras.ru/seber-trakty-tarikhy-muzee/
4. Җирле-төбәк материаллары.


## АВЫЛЫМ ТАРИХЫ – МАТЕМАТИК МӘСЬӘЛӘЛӘРДӘ


*Миннемуллина Альфида Равилевна,ученица 10 класса,*
*Научный руководитель – Бикмухаметова Голниса Рифатовна*
*МБОУ « Ныртинская средняя школа» Кукморского муницьного района РТ»*


Һәр кешенең туган иле, дөньяга беренче кат аваз салган һәм беренче тапкыр якты күк йөзен күргән җире була. Кайда гына булса да, нинди генә илләр күрсә дә, ул үзенең туган авылын яки шәһәрен беркайчан да онытмаячак. Туган ил – ул әни кебек, һәр кешенең тормышында бары бер генә була. Без күп очракларда, халкыбыз турында, аның каян барлыкка килүен белмибез, яисә бөтенләй белергә теләмибез. Ләкин һәрбер авылның, аның нинди булуына кармастан бик кызыклы тарихы була, әгәр дә кем дә булса аны өйрәнергә теләсә ул бу турыда беркайчан да укенмәячәк. Авыл язмышы кеше язмышына тиң. Авыл туа, буыннар үзгәрә, ул яши һәм картая. Бары тик үз чыганагын, тамырларын белгән кеше генә үзен Рәссәй дәүләтенең чын гражданины һәм патриоты диеп әйтә ала. Безнең илебезнең тарихы, кече авыллар тарихы белән аерылгысыз бәйле. Һәр авылның үз үзенчәлекләре бар, ләкин бердәм булганда гына ул тулы. Без туган, яшәгән, укыган, эшләгән җиребез турында күбрәк белү максатыннан мин үзебезнең төбәгебез турында материал җыйдым, мәсьәләләр төзедем һәм аларның чишелешен таптым.

Мин өстәмә рәвештә математика белән шөгелләнәм һәм Д. Пойяның: “Мәсьәләне аңлау гаты җитми, аның чишелешен табу теләге кирәк. Авыр мәсьәләнең чишелешен табу бары

тик көчле теләк булганда гына мөмкин. Көчле теләк булганда гына чыгу юллары табылачак!” – бу сүзләре белән тулысынча килешәм.

Бу проектны математика һәм әйләнә-тирә мохитне өйрәнү дәресләрендә кулланырга мөмкин.

**Теманың актуальлеге**. Туган илгә мәхәббәт – туган йортны яратудан башлана. Туган якның тарихын өйрәнү теоретик күзаллауга зур йогынты ясый, шуңа нигезләнеп тарихи фикерләүне һәм актив тормыш позициясен формалаштыра. Туган як тарихын өйрәнү иҗтимагый мәнфәгатьләрне канәгатьләндерә, аны формалаштыра һәм үстерә.

2015 елда Нырты авылының 85 еллыгы билгеләп үтелде, шушы уңайдан файдаланып, мин, туган ягыбызның тарихын өйрәнергә булдым һәм әйләнә-тирә мохит материалларына нигезләнеп 5 – 6 нче сыйныф укучылары өчен математик мәсьәләләр әзерләдем.

**Фәнни – эзләнү эшенең максаты**: авылның һәм мәктәпнең тарихы белән якыннанрак танышу; туган төбәкне белү мәсьәләр төзүдә һәм аларның чишелешдә булыша аламы икәнен ачыкларга.

**Фәнни – эзләнү эшенең бурычлары**:

– булган җирле туган якны өйрәнү материалларын өйрәнергә;

– булган туган якны өйрәнү материалларын барларга һәм аңа яңа мәгълүматлар өстәргә;

– Нырты урта мәктәбенең 5нче сыйныф укучыларының туган якны белү дәрәҗәсен тикшерергә

– туган якны өйрәнү материалары кулланып мәсьәләләр төзергә;

**Фараз:** туган як турындагы белемнәр, мәсьәләләр төзергә һәм аның чишелешен табарга булыша.

**Тикшеренү объекты**: туган якны өйрәнүнең цифрлы мәгълүматлары.

**Тикшеренү предметы**: математик мәсьәләләр.

**Фәнни – эзләнү эшенең барышы:**

– туган як турында булган мөмкин кадәр күбрәк әдәбиятны җыярга һәм өйрәнергә;

– җыеп алган материалларны мәсьәләләр төзүдә һәм аларның чишелешендә кулланырга, нәтиҗәләр ясарга;

– үз тикшеренүләремне электрон формага урнаштыру (презентация).

Эш үз эчендә берничә этаптан тора:

1. Хәзерләнү этабы: максатлар һәм бурычлар кую; проект темасы буенча эзләнүләр һәм мәгълүматлар җыю.

2. Төп этап: җыелган материалга анализ.

3. Йомгаклау этабы: алынган мәгълүматларны төзү; тикшерү буенча нәтиҗәләр; алынган нәтиҗәләрне яклау (эш йомгаклары буенча конференция).

5-6нчы сыйныфларда бирелә торган математик материаллар илебезнең, аерым алынган торак пунктларының тарихын чагылдурычы мәсьәләләр төзергә мөмкинлек бирә.

Тик математика дәреслегендә мондый материал сирәк очрый, әмма очраса да, ул бары тик ил яки зур шәһәрләр күләмендә генә була, ә безнең авыл турында, туган як өйрәнү материалларын кулланып төзелгән математик мәсьәләләр юк. Мондый мәсьәләләр математик күнекмәләрне ныгытырга гына булышып калмый, алар шулай ук укучыларның кече ватан тарихы белән, авылыбызның икътисади тормышы белән таныштыра, авыл милегенә сакчыл карарга өйрәтә, актив тормыш позициясе барлыкка килүгә өлеш кертә.

*Математик мәсьәләләрдә минем кече ватан тарихы*

Нырты урта мәктәбенең 5нче сыйныф укучыларының (10 кеше) туган якны өйрәнү белеме дәрәҗәсен билгеләү өчен мин иң элек анкетирование үткәрдем: "Беләсең микән син?", "Үз фикереңне белдер".

Сораштыру нәтиҗәсендә, бары тик 20% укучыларның гына үз авыллары тарихын белүләре ачыкланды, әммә һәр укучы кече ватаныбыз тарихы белән якыннарак танышырга теләк белдерде.

№1. Бу сан-дата, безнең авылның тарихында иң мөһим вакыйгаларның берсе. Бу елда Нырты совхозы оештырылган булган. Бу санны табыгыз.

67,75 санын 4кә тапкырлаганнар, аннары 3кә, ә аннан соң 2гә өч тапкыр тапкырлаганнар, һәм 4574не алганнар.(1930)

№2. Авылыбызның беренче директоры кем булганлыгын белү өчен, мисалларны чишергә һәм кирәкле хәрефләрне таблицага куярга кирәк. (Плеев Рамазан)

| Р | Н | Л | Е | З | А | М | П | В |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 2:4 | 6*0.6 | 5*1.4 | 10:4 | 9-3.2 | 2.3+5.7 | 6:12 | 0,4:5 | 64 |
| *3 | +1.2 | -3.2 | -1.2 | +0.5 | :5 | *1.6 | -2,5 | :4 |
| -1.2 | :0.4 | :0.2 | *6 | :9 | -0.7 | -0.35 | +56 | -6,4 |
| :0.1 | *0.3 | *0.4 | +1.2 | *0.3 | *1.1 | +0.15 | :0,1 | +2,3 |
| | | +2.4 | :18 | :0.01 | +0.01 | :4 | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 535,8 | 10 | 0,5 | 0,5 | 11,9 |
| | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 3 | 1 | 0, 15 | 1 | 2 1 | 1 | 3,6 |
| | | | | | | |

№3. Бу мисалның җавабын тапсагыз, Нырты совхозының 2014 ел башында гомуми халык санын белерсез. (1008)

(1,88+104,12):2*12+372

№4. Безнең авылның милли составын чагылдыручы түгәрәк диаграмма төзегез. Әгәр дә анда:

- татарлар - 888 кеше .
- руслар - 67 кеше.
- керәшен татарлары - 42 кеше.
- удмурдлар - 6 кеше.
- башкортлар-1 кеше.
- үзбәкләр – 2 кеше яшәсә.




№5. Авылыбызның халык саны мәгълүматлары таблицасыннан файдаланып баганалы диаграмма төзегез:

| ел | халык саны |
|---|---|
| | |

| | |
|---|---|
| 1992 | 1500 |
| 1997 | 1465 |
| 2002 | 1390 |
| 2007 | 1223 |
| 2010 | 1090 |
| 2014 | 1008 |




№6. Ул вакытта совхозда:

| | 1957 елга кадәр | 1957 елдан соң |
|---|---|---|
| сөрү җирләре | 2378га | 13465га |
| печәнлек | 120га | 429га |
| көтүлекләр | 203га | 2288га |
| бакчалар | 12га | 45га |
| урманнар | 1058га | 1115га |

Безнең совхозда 1957 елга кадәр һәм аннан соң ничә гектар җир булганын исәпләгез. Җавапларны арларда һәм квадрат метрда күрсәтегез.

№7. Аңлатманың кыйммәтен табып, совхозда кайсы елда башлангыч мәктәп ачылганын белерсез:

16 + (100 - 90) * 5

92 - 1930 елда

54 - 1945 елда
66 - 1943 елда.

№8. Кайсы елдан мәктәп җидееллыкка күчкән?
37 + 49 – 14 * 5

16 - 1949
24 - 1950
10 – 1958

№9. Нырты мәктәбе ничә ел башлангыч мәктәп булып торган?

№10.Текста очраган саннарны, сумманың разрядлары рәвешендә күрсәтегез "Безнең мәктәп районда борынгы мәктәпләрнең берсе. 1943 елда башлангыч мәктәп ачыла. Ул кечкенә генә крестьян йортында урнаша. 1949 елда мәктәп җидееллык итеп үзгәртелә, беренче чыгарылышы 1951-1952 уку елында була. Эшләү дәверендә җидееллык мәктәпне 148 кеше тәмамлый. 1964 елда урта мәктәп итеп үзгәртелә. 1981 елда безнең мәктәп 624 урынлы яңа типовой бинага күченә ".

Мәктәп зур елгалардан еракта, урман артында урнашуына карамастан, дистәләгән авыл балаларын укытучы, тәрбияләүче, зур тормыш юлына һәм төрле уку йортларына җибәрүче үзәк мәктәп булып тора.

Еллар дәвамында мәктәпне 2000нән артык укучы тәмамлаган, аларның 50се алтын һәм көмеш медалистлар. Шул исәптән, мәктәпне тәмамлаган төрле һөнәр ияләре, безнең илнең барлык почмакларында гына түгел, аннан читтә дә эшлиләр.

Алар арасында Татарстан Республикасының атказанган артисты Юкачев Николай, медицина фәннәре кандидаты Нуриев Зөфәр, икътисад фәннәре кандидаты Харисова Лилия, техник фәннәре кандидаты Гыйниятов Хәлил бар.

№11. Николай Юкачевның кайсы елда туганын ачыклагыз?
Мисалны чишегез: 350 : х + 1886, әгәр дә х=5

№12. Әгәр дә Юкачев Николай үзенең артист эшчәнлеген 1981 башлаган булса, ул артист булып киткәндә аңа ничә яшь булган? Кызганычка каршы хәзергесе көндә вафат

Мәктәпне тәмамлаган күп кенә укучылар эре предприятиеләр, учреждениеләр җитәкчеләре булып эшлиләр. Гыйниятов Х. – Казан дары заводының генераль директоры, Бикмурзин В. – Красноярск алюминь заводының генераль директоры урынбасары, Гәрәев М. – Казан Совет районы хакиме, Хафизов Р. – авыл хуҗалыгы министрының урынбасары, Хуҗиев Р. Казан шәһәре яшелендерү үзәге башлыгы.

2006 нчы елга кадәр совхоз ел саен үз вакытында дәүләткә икмәк, бәрәңге, ит, сөт һәм башка продуктлар тапшыру планын тулысынча үтәгән.

2006 нчы елдан соң совхоз белән ООО "Вамин” идарә итә башлады, шуннан соң совхозда планнар үтәлми һәм акрынлап эшчәнлек начарая башлый. Күп кенә авыл халкы шәһәргә күченә башлады. Моңа карамастан Нырты совхозында мәктәп, хастаханә, кибет, икмәк пешерү йорты эшчәнлеге тукталмады. Авылыбыз халкы арасында үз туган җиренә хыянәт итмәгән кешеләр дә бар, алар фермер хуҗалыгы белән шөгелләнә башлыйлар. Алар: абыйлы – энеле Айрат һәм Айнур Ахметовлар мөгезле эре терлек үрчетү белән шөгыльләнәләр. Мин бу кешеләр белән горурланам. Ә менә Хамизов Илшат 2008 елдан бирле казлар үстерә һәм мондый нәтиҗәләр күрсәтә:

| Ел | Казларның баш | сатудан кергән табыш | продукциянең үзкыйммәте | Керем |
|---|---|---|---|---|

| | саны | | | |
|---|---|---|---|---|
| 2008 | 9 | - | 5000 | - |
| 2009 | 40 | 20000 | 15000 | 5000 |
| 2010 | 50 | 50000 | 20000 | 30000 |
| 2011 | 100 | 100000 | 40000 | 60000 |
| 2012 | 150 | 150000 | 75000 | 75000 |
| 2013 | 500 | 1000000 | 600000 | 400000 |
| 2014 | 1000 | 1500000 | 850000 | 650000 |
| 2015 | 1500 | 1500000 | 700000 | 800000 |
| 2016 | 1500 | 1500000 | 700000 | 800000 |

№13. "Хамизов" фермер хуҗалыгында 2008 елдан 2016 елга кадәр барлыгы ничә каз үстерелгән?

№14 2008 елдан 2016 елга кадәр фермер хуҗалыгының кереме күпме булган?.

№15. Безнең урманның иң озак яшәүче үсемлегe ничек атала? Бу үсемлек 300 елга кадәр яши (брусника).

| У | А | Б | К | Р | С | И | Н |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| -14,78 | 1,15 | -10,31 | 6,28 | 7,2 | -3,18 | -14,41 | 3,65 |

1) -7,2 + (-3,11) = 2) 9,1 + (-1,9) = 3) -17,9 + 3,12 = 4) -0,48 + (-2,7) =
5) 3,8 + (-0,15) = 6) -13,1 + (-1,31) = 7) – 0,5 + 6,78 = 8) 4,65 + (- 3,5) =

№16. Безнең урманда яшәүче иң зур хайван, аның авырлыгы 500 кг артырга мөмкин. Бу нинди хайван (поши)

| и | о | ш | п |
|---|---|---|---|
| 7/18 | -3/4 | -1/2 | -1 |

1) -1/2-1/3-1/6 =
2) -3/4-5/14+1/18 =
3) -1/3+1/4-5/12 =
4)1/9-1/3+11/18 =

Бу фәнни – эзләнү эше барышында, мин мәктәп музее, мәктәп һәм авыл китапханәләреннән күп кенә туган якны өйрәнү материалларын кулландым, математик мәсьәләләр төзү һәм чишү алымнары , авыл идарәсендәге, Нырты хуҗалыгы буенча документлар каралды, мәсьәләләр өчен кирәкле фоторәсемнәр сайлап алынды, Нырты совхозы буенча документлар өйрәнелде. Болар барысы да миңа авыл һәм мәктәп тарихын чагылдырган математик мәсьәләләр төзергә булышты.

Минем уйлавымча, авыл тарихын чагылдырган мәсьәләләр төзү һәм чишү, иҗади һәм логик фикерләү үсешенә ярдәм итә, алган белемнәрне гомумиләштерә һәм белем дәрәҗәсен киңәйтә.

Моннан тыш, әзерләгән математик мәсьәләләрне , математика дәресләрендә, математик викториналар һәм ярышлар үткәргәндә кулланырга була.

Бу тема буенча тикшеренү эше дәвам итәчәк. Әгәр укучылар конкрет туган якны өйрәнү мәгълүматлары булган математик мәсьәләләрне чишсәләр, аларның математик сәләтләрен үстерү генә түгел, ә туган якның үткәнен һәм бүгенгесен өйрәнергә дә мөмкинлек бирәчәк.

*Кулланылган әдәбият*

1. Математика: 5 класс: учебник для учащихся общеобразовательных организаций / А.Г. Мерзляк, В.Б. Полонский, М.С. Якир.. - М.: Вентана-Граф, 2014. – 304 с.

2. Горкин А.П. Математика. Информатика: Энциклопедия – М.: ЗАО «РОСМЭН-ПРЕСС», М34 2007. – 544 с.

## ТУГАН АВЫЛЫМ БУЙЛАП СӘЯХӘТ

*Мухарлямова Гүзель Илшатовна, ученица 5 класса.*
*Научный руководитель – Хисматова Айсылу Хадиулловна*
*МБОУ "Яныльская средняя школа"*
*Кукморского муниципального района РТ*

Фәнни – тикшеренү эшенең темасы: “Авылымның үткән тарихы”. Туган як, туган җир, туган авыл... Аларда безнең үткән тарихыбыз, моң – зарларыбыз, кайгы – шатлыкларыбыз чагыла. Еллар үткән саен, авылларның да йөзе үзгәрә: йә алар үсә, зурая яки киресенчә кечерәя, бетүгә йөз тота. Әлеге авылымның гасырларга тоташкан үз тарихы бар. Мине дә авылымның тарихы кызыксындырды. Шул максат белән, мәктәп музеена юл тоттым. Музей җитәкчесе Алмаз Нургалиевич авыл тарихына багышланган бүлек белән таныштырды. Риваятьләргә нигезләнеп, авылымның барлыкка килүен тикшеренү формасында алып барырга уйладым. Бу тикшеренүләр барышында гаять катлаулы **проблема** белән очрашырга туры килде. Бу проблеманы сорау рәвешендә “Һәр кеше өчен дә туган җиренең тарихын белү заруримы?” дип атап булыр иде.

Проблемага ачыклык кертеп, күп еллар элек барлыкка килгән риваятьләргә нигезләнеп, авылымның барлыкка килү тарихын күрсәтү һәм хәзерге буынга туып-үскән җиреңнең тарихын белүнең никадәр мөхим булуын аңлату**максатын** куйдым. Максатка ирешү өчен түбәндәге бурычлар билгеләнде:

1. Риваятьләрнең ни сөйләвен ачыкларга;
2. Күмәк хуҗалыкның беренче исемен һәм эшчәнлеген ачыкларга;
3. “Нәрсә ул МТС?” – дигән сорауга җавап табарга;
4. Авылымның табигатен күзәтергә;
5. Бүгенге көндә авылымның уңышларын күрсәтергә;

Эзләнү – тикшеренү өлкәсе: авыл тарихы турында теоретик һәм практик дәлилләр.

Эзләнү – тикшеренү предметы: тарихи язмалар.

Эзләнү – тикшеренү эшенең максаты: авыл исеменең каян барлыкка килүен ачыклау, элек авылда яшәгән кешеләрнең тормышын күзалдына китерү, шул чордагы авыл үсешен, табигатен күзәтү һәм хәзергесе белән чагыштыру.

Эзләнү – тикшеренү эшенә билгеләмә: эзләнү – тикшеренү эше ул – теоретик белемнәрне практика белән бәйләп күрсәтелгән иҗади эш яки фәнни хезмәт. Кушыматада элеккеге авыл фотографияләре урын алды.

### Авылымның исеме каян барлыкка килгән? Риваятьләр ни сөйли?

Туган төбәкне сайлап алмыйлар. “Новое село Головино”, “Яңа ил”, “Яңил”, “Янил”. Риваятьләр ни сөйли? Риваятьләргә караганда Янил авылына XVI – XVIII гасырларда нигез

салынган. Царизмның христианлаштыру сәясәтенең иң куәтле чагы. Авыл халкын куркыту, яисә кызыксындыру белән христиан диненә күчерәләр. Риза булмаганнар исә, төрлесе – төрле якларга китәргә мәҗбүр була. Өлкәннәрнең сөйләүләре буенча, элек бер яктан ерып чыккысыз сазлык, икенче ягыннан кара урманнар белән әйләндереп алынган була ул авыл. Сазлыкларда язын кыр казлары, кыр үрдәкләре оя корып, бәбкә чыгарганнар. Иң әүвәл бу урыннарга удмурт - марилар килеп урнашкан. Урман кисеп йорт, каралты – куралар торгызганнар, үзләренә чәчүлек җир әзерләгәннәр.

Табигатьнең гүзәл почмагы булган Янилгә иң әүвәл өч гаилә нигез салган диләр. Мамадыштан ике, Арчадан бер гаилә килеп төпләнгәннәр. Алар урыс һәм удмурт милләтендәгеләр. Еллар үткән саен алар янына христиан диненә күчкән татарлар (керәшен татарлары) да килеп урнаша тора. Халык бу авылга "Новое село Головино" ди исем бирә. Авыл зурая, тирә – юньгә таныла бара.

Татарлар "Новое село Головино"ны үзләренчә татарчалаштырып "Яңа авыл" дип атый башлыйлар. Тора – бара исә аны "Яңа ил"гә алыштырганнар. Читтән күчеп килүчеләр аны тагын да җиңеләйтеп "Яңил" дип, аннан инде бүгенгә килеп җиткән исеме "Янил"гә әверелә.

Янил авылының барлыкка килүе турында икенче риваятьтә исә бөтенләй башкача әйтелә: "Бөр" елгасының сул ягында торучы удмуртлардан тыш, елганың икенче ягына татарлар килеп урнашалар. Алар йортлар төзи башлыйлар һәм моны күрше авыллар, үтеп баручылар "Яңа ил" дип атыйлар, чөнки яңы җирдә урнаша. Гомерләр уза тора, авылның исемен җиңеләйтеп "Яңил", ә соңыннан исә "Янил" дип йортә башлыйлар. Шулай итеп Янилдә ике диндәге кешеләр яши башлый. Мөселманнар һәм керәшен татарлары.

**"Кызыл сукачы" күмәк хуҗалыгы**

1920 елда Янил 200 хуҗалыклы эре авыл булган. Халык саны чама белән 1500 кеше исәпләнгән. Биредә төрле милләт вәкилләре: удмурт, мари, рус, татарлар дус, тату гомер кичерәләр. Авылда тегү, шәл бәйләү киң таралган була. Тегүчеләр сарык тиресеннән толыплар, туннар, кайры туннар, шулай ук бишмәтләр, костюмнар тегәләр, ә хатын – кызлар өйләрендә күлмәк тегәләр, оекбашлар, мамык шәлләр бәйлиләр. Кәҗә мамыгын Казахстаннан алып кайталар. Гадәттә авыл кешеләре тегү – бәйләү белән авыл хуҗалыгы эшләре тәмамланганнан соң шөгыльләнә, чөнки төп эшләре кырчылык һәм терлекчелек була.

1929 нчы елның мартында авылда беренче күмәк хуҗалык төзелә. Ул 24 шәхси хуҗалыкны берләштерә. Колхозга беренчеләрдән булып Михаил Филиппов, Анисья Григорьева, Хәмидулла Ильясов керә. Күмәк хуҗалыкка "Кызыл сукачы" дигән исем бирәләр һәм рәисләре итеп Михаил Филипповны сайлыйлар. Берләшкән хуҗалыкның 6 аты, агач сука һәм тырмаларыннан гайре берние дә булмый. Җирне сука белән эшкәртеп, ашлыкны урак белән урганнар.

Вакытлар үтә. "Кызыл сукачы" да берникадәр ныгый, эш ысуллары үзгәрә. Колхозларны ныгыту сәясәте башлана. Хуҗалыкка рәис итеп партия әгъзасы Салават Бикчәнтәев җибәрелә. Колхозда 150 ат асрарлык абзар, ашлык амбары төзелә. Бригадалар арасында ярыш оештырылып, алдынгыларга хезмәт көненә 10 кг., арттарак калучыларга 7 кг. исәбеннән ашлык өләшенә.

Күмәк хуҗалык елдан – ел ныгый, үсә бара. Күрсәткечләрен исәпкә алып, 1935 елда колхозчы ударникларның II Бөтенроссия съездына делегат җибәрү хокукы бирелә. Андый бәхет колхозчы Сания Абдуллинага елмая.

Авылда культура-агарту эшендә дә зур үзгәрешләр барлыкка килә. Авыл советы председателе Хисматов Шәрәф булган вакытта беренче мәртәбә библиотека һәм балалар бакчасы өчен йортлар салына һәм файдалануга бирелә, клуб төзелә. Колхоз үсә, хуҗалык ягыннан ныгый, фермалар төзелә. Беренче мәртәбә 20 баштан торган дуңгыз фермасы салына. Безнең Янил авылыннан Бөек Ватан сугышына 210 кеше киткән, шулар арасыннан 80 кеше яу кырында ятып кала. Безнен якташларыбыз сугыш кырларында искиткеч батырлык үрнәкләре күрсәтәләр. Мәсәлән, авылдашабыз Иванов Василий Дан орденының дәрәҗәсе белән бүләкләнә.

**Нәрсә ул МТС?**

1933 нче елда авылда МТС төзелә. Шуннан соң колхозда авыл хуҗалыгы машиналарының саны арта, колхоз механизаторлар хәзерләү өчен кыска сроклы курсларга үзеннән кешеләр җибәреп укыта башлый.

Сугыш авыл кешеләре өчен гаять зур сынаулар алып килде. Ир-егетләр яу кырына киткәч, буразнага яланаяклы малайлар, бабайлар басып, күтәрәмгә калган атларны сабанга җиксә, трактор руле артына хатын-кызлар утырды 1942 нче елның 4 январенда чыккан газетаның баш мәкаләсендә шундый юллар бар: «Бик кыска гына вакыт эчендә хатын-кызлар катлаулы авыл хуҗалыгы машиналарын үзләштерделәр, трактор руленә, комбайн штурвалына бастылар һәм фронтка киткән тәҗрибәле тракторчыларны һәм комбайнчыларны бик уңышлы алмаштырдылар. Хәзер бер Янил МТС ында гына да хатын-кызлардан 52 кеше тракторчы булып эшлиләр.

Җәмлиха Баймакова тракторда эшли башлаганнан бирле норманы 150-170 %ка үтәп барды, иптәш Федорова җитәкчелек итә торган бригада еллык планны 120% ка үтәде…»

Газетаның 1942 ел, 16 июль санындагы Янил МТСы политбүлеге хезмәт-кәре С.Шакиров язган мәкаләдә Лотфулла Фәйзрахманов бригадасының еллык планы 10 июльгә кадәр үк 100,6% ка үтәве турында хәбәр ителә. «Иң зур күрсәткечкә тракторчы Бикә Гыйззәтуллина иреште. Ул 272 гектар җир эшкәртеп, 500 кг. ягулыкка экономия ясады. Хатын-кыз трактор бригадалары ярышында 1942 ел йомгаклары буенча республикада беренче урынны Кукмара районы Янил МТС ыннан Хәтимә Хөснитдинова бригадасы яулый. Аңа комсомол өлкә комитетының күчмә Кызыл Байрагы Гыйззәтуллинага «ССРрның иң яхшы тракторчысы дигән исем бирелә, значок һәм таныклык тапшырыла.

МТСны күп еллар дәвамында Югары Совет депутаты Сәмигулла Вәлиев җитәкли. 1958 елда, колхозларның үзләренә техника сатып алу хокукы бирелгәч, МТС эшләүдән туктый.

*I Iбүлек*. **Авылым табигатендә истәлеклке урыннары**

Янил авылы, бик матур урында урнашкан. Авылыбызга ямь биреп буеннан –буена тау сузылган. Бу тауның төрле өлешләренә элек-электән атамалар бирелгән: Вәли тавы, Кала тау, Тәбәнәк тау, Кәҗә тавы, Янил тавы, Саклау тавы, Бакыр базы һ.б. Әлеге тауларның үз тарихы, үз истәлеге бар.

Кала тавында артыш күп үскәнгә **Артышлы тау** дип тә атыйлар.

Без тәбәнәк тау - Саклау тавы алдында. Биредә чикләвек агачлары күп. Авыл халкы анда чикләвеккә йөри. Урманның саф һавасы арган йөрәкләргә җиңеллек бирә. Элек әлеге тау сакланган, махсус каравылчысы булган. Авыл халкы төрле вакытта килеп чикләвек җыя алмаган. Исеме дә шуннан килеп чыккан.

Тау итәге буйлап бормаланып-бормаланып Бөр елгасы ага.

Бу су Балтачның Бөрбашурманыннан башланып, Киров өлкәсенең мул сулы Нократына коя. Яз көне әлеге елгада урманнан агып чыккан бик күп бөре кабыклары ага, шуңа күрә исеме дә Бөр елгасы дип атала. Җәй айларында елга ярында кеше өзелми.

Елгага бик күп чишмәләр, инешләр кушыла. Һәр чишмәнең үз исеме, үз атамас бар.

**Вәли чишмәсе.**

Тау култыгында, Вәли тавы итәгендәага ул.

Элек авылдан читтә, тау буенда Вәли бай яшәгән. Бик саран булганга, үз биләмәсенә ул беркемне дә кертмәгән. Шул заманнардан бирле ул тауны - Вәли тавы, чишмәне - Вәли чишмәсе дип атыйлар.

**Камали чишмәсе.**

Җирле риваятьләр буенча, чишмәне Камали әби чистартып, карап торганга, аны – Камали чишмәсе дип атыйлар.

**Көтүче чишмәсе.**

Элеккеге елларда авыл көтүчесе Хафиз исемле агай, тау астыннан ерак түгел бер чишмә агуын күрә.Су алырга уңайлы булсын өчен, чокыр казый, чишмәне торгыза. Бүгенге көндә "Көтүче Хафиз чишмәсе" кыскартылып, бары тик "Көтүче чишмәсе" дип кенә йөртәләр.

**Миңлегол чишмәсе.**

Авыл башында, Бөр елгасы янында гына бик матур өй эчендә, чәчәкләр арасыннан авыл башы чишмәсе агып ята. Бу чишмәне Миңлегол абзый Юнысов карап – чистартып торган. Хәзерге вакытта аны **“Миңлегол чишмәсе”** дип атыйлар.

Янил авылының тау буенда барлык узган- барганнарны тәмле суы белән сыйлап **“Узгынчылар”** чишмәсе челтерәп ага.

Янил авылының зур сәүдә базары белән данлыклы булуы бу төбәктәге һәркемгә мәгълүмдер. Һәр атна саен бирегә тирә-як авыллардан бик күп сәүдәгәрләр, сатып алучылар килә торган була. Ул вакытта зур юллар булмаган. Шунлыктан Малмыж Сәрдек яклары, мари һәм ар авылы кешеләре тау өстеннән үткән басу юлы аша килә торган булганнар. Малларның, җигеп килгән атларның сусауларын басарга Бөр елгасы булса да, ул тирәдә чишмә булмаган. Тау буендагы дымсу җирдән чишмә чыкканын күреп ул урында чишмә казып куйганнар. Әлеге чишмә яныннан узган һәр юлчы туктап су эчеп китә торган булган. Хәттә халык телендә “Узгынчылар чишмәсенең суын эчеп китсәң юлың уңа”- дигән әйтем дә йөри башлаган. Чишмә бүгенге көндә дә яхшы хәлдә. Аны карап, тәрбияләп торалар.

Бу чишмә бүгенге көндә дә үзенең яныннан узучыларны чиста, саф Һәм салкын суы белән сөендереп тора. Бу чишмә авыл халкының көндәлек тормышында кулланыла Һәм эчә торган су булып тора.

*III бүлек*. **Хәзер менә без кемнәр? Бүгенге көндә Янил авылы**

Вахитов исемендәге җитештерү кооперативы республиканың төньяк – көнбатышында, Казаннан 150 км., район үзәге Кукмарадан 25 км. ераклыкта урнашкан. Әлеге хуҗалык территориясендәге Янил авылы җирлеге 3 авылны берләштерә. Янил авылында 171 хуҗалыкта 621 кеше, Вахиттә 214 хуҗалыкта 864 кеше, Бөярдәге 4 хуҗалыкта 9 кеше яши.

Хуҗалыкта 1320 мөгезле эре терлек, 2000 дуңгыз асрала.

Хәзерге көндә Янил авылында 3 катлы мәктәп, балалар бакчасы, почта бүлеге, медицина пункты, хуҗалык идарәсе, 4 кибет, клуб, мал фермалары, амбар, МТС урынына аграр көллият урнашкан.

Минем туган авылымны
Янил дип атаганнар.
Табигатен, матурлыгын
Саклый анда туганнар.
Безнең туган авылыбыз
Таулар белән данлыклы.
Бормалы Бөр елгасы да
Гади түгел, балыклы.
Авылыбыз кырларында
Үсә бодай, кукуруз.
Ашлыклары бик уңа.
Тула амбарларыбыз.

***Йомгаклау***

Фәнни – тикшеренү эшенең темасы: “Авылымның үткән тарихы”.Теманы сайлагач, проблемалы сорау куйдым: “Туган җиреңнең тарихын белү кирәкме?” Әлбәттә, түбәндә бирелгән бүлекләр һәм параграфларда мин бу сорауны чиштем дип уйлыйм. “Авылымның исеме каян барлыкка килгән?”, “Янил авылы үсеше” һәм “Хәзер менә без кемнәр?”дигән бүлекләр ярдәмендә теманы ачыклауга ирештем дип саныйм.

Туган нигезеңнең килеп чыгышы, үсеш – үзгәреш тарихы һәр заман өчен дә актуаль проблема, чөнки тормыш алга барган саен туган авылың булсынмы, яисә шәһәрме ул, һичшиксез, күзгә күренерлек үзгәрешләр кичерәчәк. Һәм бу үсеш – үзгәреш тарихын җыйнап бару һәр үткәнен хөрмәт итүче кешенең төп бурычы булуын ачыкладым. Әгәр без, киләчәк буынга патриотлык, ата – бабаларыбызга булган хөрмәт хисләрен тапшырасыбыз килә икән, без иң беренче чиратта аларга туган нигезләре турында бай мәгълүмат калдыруны күздә тотарга тиешбез. Чөнки үткәнен белмәгән халык, үзен тулы мәгънәсендә халык дип саный алмый.

Йомгаклап, шуны әйтәсе килә, без, яшь буын туган ягыбызның киләчәге өчен җаваплы кешеләр. Туган төбәгебезнең тарихын җентекләп өйрәнеп, эш – гамәлләребезне аның табигатенә зыян китермәслек итеп оештырырга тиешбез. Шулай булганда гына без сәламәт һәм бәхетле кешеләр булырбыз, бездән соң килгән буынга бай табигый мирас калдырырбыз.

*Файдаланылган әдәбият*

1. Габделбәр Ризванов, Расим Ризванов "Туган җирем – гомер бишегем.
2. Хасанов М. Х. Татар энциклопедия сүзлеге. – Казан, 1999.

## МИҢГОЛ ГАЛИЕВ – МАМАДЫШ РАЙОНЫНЫҢ ГОРУРЛЫГЫ

*Сонгатуллин Гадел Рамилович, ученик 10 класса*
*Научный руководитель – Хасанова Асия Альфетовна*
*МБОУ «Олуязский лицей» Мамадышского муниципального района Р Т*

Һәр төбәкнең үзенең күренекле шәхесләре була. Алар турында горурланып сөйләнелә, кылган гамәлләре хөрмәтләнә, яшь буынны да шулар үрнәгендә тәрбияләү максаты куела. Әйе, безнең якташларыбызның күбесе районнан читтә - республика күләмендә һәм хәтта Россия күләмендә дә танылган шәхесләр. Без алар турында телевидение тапшыруларын карап, матбугат битләреннән укып та белә алабыз. Һәр укучы, минемчә, үзе яши торган төбәкнең табигатен, аның үзенчәлекләрен, халкын, традицияләрен, мәдәниятен, тарихын яхшы белергә тиеш. Шуңа күрә дә Мамадыш районы Иске Комазан авылынннан чыккан күренекле һәм талантлы якташыбыз – Миңгол Галиев белән таныштырасым килде.

"Миңгол Галиев – Мамадыш районының горурлыгы" дип исемләнгән фәнни-эзләнү эшемә түбәндәге **максатларны** куям:

1.Мамадыш районы Иске Комазан авылыннан чыккан Миңгол Галиев турында тирәнрәк мәгълүмат алу;

2. Мөстәкыйль иҗади фикерләү, язу кыйммәтләрен үстерү;

3. Очерк жанрындагы әсәрне язу күнекмәләрен булдыру;

4. Туган җиргә мәхәббәт, туган төбәккә бәйле күренекле кешеләргә хөрмәт һәм горурлану хисләре тәрбияләү.

**Өйрәнү объекты** – хөрмәткә лаеклы Татарстанның халык артисты, җырчы Миңгол Галиевның тормыш юлы, иҗаты

**Предметы** - әдәбият фәне.

Фәнни эшемдә өлешчә эзләнү, тикшеренү, анализ кебек алымнар файдаландым. **Көтелгән белем нәтиҗәләре:**

-якташыбыз турында мәгълүмат алу;

-тормыш юлын, иҗатын анализлый белү;

- әңгәмә-дискуссияләрдә катнашу, үз фикереңне әйтү;

-милли үзаң формалашу, туган төбәктә намуслы хезмәт итү теләге уяту;

-үз халкыңның рухи байлыгын өйрәнү, аны үстерү һәм саклау өчен үзеңнән өлеш кертүгә омтылыш тәрбияләү.

**I. Әнием моңының бер тамчысы...**

Җырларымны сиңа багышлыйм,
Мактау сүзем синең хакыңда;
Сулышларым сәлам булып кайтсын,
Туган-үскән авылым халкына, -

бу шигырь юлларын Вахит ага Галиев - шагыйрь, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре - үзенең туганнан-туган энесе Миңгол Галиевка багышланган дисәк, һич ялгыш булмас.

Әйе, бүгенге көндә якташыбыз Миңгол абый Казанда яшәп иҗат итсә дә, күңеле белән ул һәрвакыт туган авылында – Иске Комазанда. Еш кына авылга кунакка кайтуы, халкыбызның Сабантуй бәйрәмнәрен онытмавы, туган-тумачаларының хәлен белеп йөрүе, авылдашларына бәйрәм сәламы юллавы, үзенең шәкертләре белән бергәләп басу-кырларда, мәдәният йортларында чыгыш ясавы, мәктәп укучылары белән очрашулар үткәрүе, яшь талантларны барлавы шул турыда сөйли. Баш-аягы белән педагогика һәм иҗат эшенә чумган Миңгол абый каян шулай вакыт таба соң? Минемчә, сәбәп вакытны табу - тапмауда түгел, ә мәхәббәттә. Туган җиргә, туган нигезгә, нәсел-нәсәбәте дәвам иткән туган-тумачаларга, авылдашларга мәхәббәт йөртә аны. "Моңсыз, көйсез тормышны, гомумән, күз алдына да китерә алмыйм", - ди Миңгол Галиев һәм түбәндәге шигъри юлларны көйгә сала:

Бабайлар моңыннан башка-<br>
туган җир ятим бит ул!!!<br>
Көйсез-моңсыз үткән көннәр-<br>
яшәлмәгән көн бит ул!!!

Бүгенге көндә Татарстанның халык артисты, җырчы Миңгол Галиевны белмәгән, искиткеч моңлы тавышына сокланмаган кеше юктыр. Юкка гына аны "моң солтаны" дип атамыйлар. Борынгыдан килгән әби-бабайларның моңын дәвам итә ул. Төбе-тамырлары белән җиргә береккән гап-гади авыл кешесенең моңын үзендә йөртә күренекле якташыбыз. Нәселләрдә җырга-моңга гашыйклар күп Галиевларның. Миңгол абыйның Салих атлы абыйсы, җырчы булу өстенә, оста гармунчы да булган. Туган абыйсы Вахит ага Галиев, 85 яшь тутыруга карамастан, һаман да сәхнәдә: татар халык көйләре белән бергә үзе язган җырларны да башкара. Миңгол абыйның әтисе Вагыйз бабайның сеңлесе Зәйтүнә әбинең оныклары Салих һәм Вакыйф Садыйковлар да һәвәскәр җырчылар буларак, район күләмендә танылып өлгерделәр. Бәйрәм вакытларында авылдашларын оста башкарылган җырлары белән сөендерәләр.

Музыка кеше күңеленә искиткеч дәрәҗәдә көчле тәэсир итә. Аның йогынтысы бишек көеннән башлана. Ана моңы - бишек җыры. Музыка, җыр, моң белән тәрбияләнгән бала начар кеше булып үсми. “Көйләп Коръән укыган, бәетләр, мөнәҗәтләр әйткән әнием Миңсылуның моңлы авазы бүген дә күңелемдә чыңлый. Гаҗәеп көчле тәэсиргә ия моңлы кеше авазын бернинди дә музыка уен коралы алыштыра алмый", - ди Миңгол абый, үзенең сагышлы хисләре белән уртаклашып.

Миңгол Галиев – сугыш чоры баласы. Әтисе Вәгыйзь абый сугышның беренче көннәреннән үк хәрби хезмәткә алына. Хәбәрсез югалуы турында хат килгәндә, аңа әле бары 35 яшьләр чамасы гына булгандыр. Кечкенә Миңгол 1941 елның 27 августында, нәкъ урак өстендә бишенче бала булып дөньяга аваз сала. Җиде айлык кына булып дөньяга килгән бу баланың ничек исән калганын бер Ходай гына белә! Иң олысына 9 яшь кенә булган, Миңсылу апа тормышын алып барырга кайлардан көч тапкандыр?.. Ул чактагы авырлыклар сугыш чоры балалары өчен яхшы таныш. Бәлки нәкъ менә күңел түреннән саркып чыккан моңы, сагышлы җырлары, мөнәҗәтләре булышкандыр, киләчәккә өмет уяткандыр ялгыз анага. Миңсылу апа шул ук авылда мулла гаиләсендә туып үскән, тырыш, уңган, бик укымышлы хуҗабикә була. Коръән укыган, аның күп кенә аятьләрен яттан белгән. Гарәп, латин, кирилл графикаларын да яхшы үзләштергән. Кечкенәдән еш авырса да, чандыр гына гәүдәле Миңгол, үҗәтләнеп, нинди эш эләксә, шуңа ябыша, гаиләсенә ярдәм итәргә тырыша. Мәктәптә укыган чакта ук йөкче булып эшкә урнаша, кичләрен атлар егәрләп көтүгә алып чыга. Әнисенең моңлы-сагышлы көйләрен, мөнәҗәтләрен, бәетләрен тыңлап, күңеленә сеңдереп бара. “Кечкенәдән үк җырлый башлаганмын. Күршедә Мәрҗән исемле кыз бар иде. Ул гел борын эченнән үзенчә көйләп йөри, мин шуңа

охшатып җырларга тырышам, тик килеп чыкмый. Бәлки шуның шаукымы кагылгандыр”, - ди Миңгол абый үзе.

1957 нче елда укучы-яшьләрнең Казанда уткәрелгән республика фестивалендә Миңгол Галиев, 8 нче сыйныф укучысы, лауреат исеменә лаек була, диплом ала. Укытучысының котлап, матур сүзләр әйткәне әле дә исендә. Ә 10 нчы сыйныфта укыган чагында мәктәпләренә күренекле композитор Александр Ключарев белән фронтовик шагыйрь Мөхәммәт Садри килә. Укучылар аларга концерт күрсәтә, мәктәптә танылып өлгергән Миңгол да чыгыш ясый. Ул җырлаганда фортепьянода уйнаган А. Ключарев, концерттан соң, егетне рухландырып: “Энем, синнән, һичшиксез, халык җырчысы чыгачак, сиңа укырга кирәк!” – ди.

“Укып бетергәч, кая барыйк икән дип уйлашабыз. Әни, әй кеше балалары булган инде ул, безнекеләрдән әллә ни юк, дигән кебек әйтеп куйды. Шул сүз миңа җитә калды, арттан эткән кебек чыгарып җибәрде. Хәзер генә артистларны яраталар. Ул чакта төрле сүзләр йөри иде. Шуңа, читенсенеп, беркемгә әйтмәдем. Хатыным Фәния белән дуслашып йөри башлаган идек, хәтта ул да белми калды, ахырдан үпкәләгәне дә хәтердә әле”, - дип көлеп искә ала Миңгол абый. Шулай да югалып калмый, туп-туры Казанга – консерваториягә килә. Укырга керергә теләүче 50 ләп егет-кыз арасында иң яше һәм бердәнбер авыл малае була ул. Имтихан бирергә аны беренче итеп чакыралар. Имтихан алучыларны кыюсыз гына кереп баскан малай белән мәшһүр җырчыбыз Фәхри Насретдинов таныштыра: “Менә, иптәшләр, Сезнең алдыгызда – көтүче егет!..” Бу сүзләрне яшь Миңгол мактау сыман кабул итә һәм, күңеле канатланып, җырлап җибәрә. Бәхетенә, аны консерваториягә кабул итәләр. Тик авылда үзенчә җырлап үскән егеткә уку җиңел генә бирелми. Ул әле ноталарны белми, аңа музыка теориясе дә таныш түгел, җитмәсә, тавышны да фәнни кысаларга кертәсе: авызны дөрес итеп ачарга, дөрес итеп сулыш алырга да өйрәнәсе икән... Ике ел укыгач, Миңгол Галиев үз теләге белән хәрби хезмәткә китә. Кайткач, укуын дәвам итәргә була. Студент елларында Миңгол гардеробта да, мәдәният йортында сакчы, урам җыештыручы булып та эшли. Шулай итеп үзенә өс-баш юнәтә, тамагын туйдыра. Тора-бара үзе дә яшь җырчыларны музыка серләренә төшендерә башлый – Татарстанның X еллыгы исемендәге Мәдәният сараенда хор коллективын җитәкли. “Укучыларымны өйрәтә-өйрәтә, үзем дә өйрәнеп беттем”, - дип шаярта ул. 1960 нчы еллар уртасында М. Галиев үзешчән сәнгатьтә актив катнаша башлый һәм үзенчәлекле тавышы белән тиз арада танылып та китә. “Тормыш җыры”, “Һаман яратам”, “Сез иң гүзәл кеше икәнсез”, “Мәтрүшкәләр”... Кыйбла, дин, әти-әни, туган як, мәхәббәт – барысы да бар аның репертуарында. Һәр җыры халыкчанлыгы һәм үзәкләрне өзәрдәй моңы белән аерылып тора. “Милләтне дин һәм җыр саклый. Халкыбыз гомер-гомергә моңлы җырлар, мөнәҗәтләр, бәетләр көйләп, сагыну-сагышларын, түзә алмастай йөрәк яраларын баскан, шулай итеп аларны җиңелрәк кичергән, сабыр булып кала алган. Бүген халык күбрәк күңел ачуга гына корылган тамашаларга өстенлек бирә. Безгә үз тормышыбыз, рухи байлыгыбыз, динебез кебек мәңгелек темалар турында җырларга кирәк. Ягымлы аваз, моңлы аһәң кеше күңелен тизрәк яулый. Җыр аша кешене дәваларга да мөмкин. Студент чагымда каты гына авырып киттем. Миңа куелган диагноз белән җырларга ярамый иде. Әмма бик талантлы табиб Мәрвәр Уразаев кабат тикшергәннән соң: “Син җырлаганга күрә яшисең”, - диде. Кеше авырганда да бит музыкага охшаш авазлар чыгара, ыңгыраша. Галимнәр күптән ачыклаган, бу үзенә күрә бер иммунитетны ныгыту чарасы икән”, - ди Миңгол абый.

Бу хәлләргә бик күп вакытлар узган инде. Хәзер Миңгол Вагыйз улы Галиев – танылган татар җырчысы, мөгаллим, Татарстан Республикасының халык артисты. Бик күп еллар Казан дәүләт педагогика университетының музыка факультетында педагогик, фәнни хезмәтләр белән бергә концерт һәм музыкаль-агарту эшчәнлеген дә алып барган шәхес. Аның шәкертләре Бөтенроссия, халыкара дәрәҗәдә лауреатлар һәм дипломантлар, мактаулы исемнәр алган җырчылар.

Татарның җыр сәнгате үсешенә зур өлеш керткән Миңгол Галиевның репертуарында композиторларыбыз һәм халкыбыз иҗат иткән 800дән артык әсәр бар. Фондларда аның башкаруындагы йөздән артык татар җыры, мөнәҗәтләр саклана.

**Моң тәрбиячесе**

Миңгол Галиев – гомерен татар моңын саклауга, баетуга, яшьләргә музыка тәрбиясе бирүгә багышлаган шәхес. Кая гына барса да, җырларга өйрәтүдән тәм һәм ямь табып яши. Аны әллә кайлардан өенә кадәр эзләп киләләр. Бүгенге көндә ул А.Алиш исемендәге балалар иҗат сараенда, Азино балалар иҗат үзәгендә эшли. Күптән түгел Казан финанс, икътисад һәм информатика институты каршында вокал мәктәбе булдыруга ирешкәннәр. 2016 нчы җәй башында Татарстан Халыклар дуслыгы йортында шәкертләренең тәүге концертын оештырды.

Миңгол аганың укучылары төрле. 3 яшьлек балалардан алып, 85 яшькә кадәргеләр дә йөри аңа. Алар арасында татарлар да, башка милләт вәкилләре дә бар. Мисалга, Казан шәһәренең Киров һәм Мәскәү районнары Залесный мәдәният үзәгенең "Татар гармуны" ансамбле җырчысы Зөлхәбирә апа Сәләхетдинова быел үзенең 88 яшен тутырды.

Моннан тыш, Миңгол абый "Фантазия" хатын-кызлар джаз ансамблендә шөгыльләнә, Алабуга шәһәренә, туган ягы Мамадышка йөреп тә дәресләр бирә.

"Бер ара мәктәп укучыларын мәдәният йортларына концерт, тамашаларга йөрүдән тыя башладылар. Моңа һәрчак каршы булдым, сәнгать белән араны өзәргә ярамый. Укытучың белән янәшә утырып спектакль карау, ун ел буе тәрбия бирүдән көчлерәк ул. Кеше рухын игелекле итеп тәрбияләүдә дин һәм музыканың, сәнгатьнең роле зур", - ди Миңгол Галиев. Аның дәресләре җырларга өйрәтү белән генә чикләнми, укучысының күңеленә үз халкының үткәненә, гореф-гадәтләренә мәхәббәт орлыклары салырга да өлгерә. Миңгол абыйның методикасы үзенчәлекле. Гадәттә, опера җырчылары авызларын зур ачып, кычкырып җырлый. Вокал дәресләрендә дә шулай өйрәтәләр. Әмма Миңгол Галиев җырның моңына, хис-тойгыларга игътибар итә. Аныңча, җырчы артык көчәнеп җырларга тиеш түгел. "Шагыйрь хис-кичерешләрен шигырьгә сала. Композитор аны моңга төрә. Бу ике шәхеснең иҗатын халыкка җиткерүдә җырчы ярдәм итә. Моң ул – җан авазы. Кеше хискә бирелеп җырлаганда, ул үзеннән-үзе туа. Мәсәлән, руслар "турырак" җырлый, итальяннарда югары тавыш, һинд җырлары бөтенләй икенче төрле, яңгыравыклы булулары белән аерылып тора. Безгә башка халыклар артыннан куарга кирәкми. Авызыңны, Тукай әйткәнчә, кәгазь калынлыгы гына ачып, артык көчәнмичә, сөйләшкәндәге кебек, хис-тойгыларга бирелеп җырлау мәгъкуль. Татар җыры үз асылын югалтмасын иде", - ди Миңгол абый. Аның хыялы – С.Сәйдәшев, Т.Гыйззәтләр заманындагы татар музыкаль театрын кайтару. "Гомерем буе образга кергән иң көчле җырчы ул – драма артисты дип санадым. Өметле укучыларыма һәрвакыт театр факультетына керегез дип әйтә киләм. Соңгы елларда укыткан шәкертләрем – Раил Шәмсуаров, Гүзәл Гөлвердиева бүген Камал театрында эшли, Ваһапов фестивале лауреаты Гөлсирин Абдуллина җыр сәхнәсендә танылды. Укучыларым яраталар, концертларына чакыралар, минем хакта горурланып сөйлиләр икән, шуннан да зуррак бәхет була аламы?! – дип әйтә Миңгол абый.

**III. Ярату шундый була!**

Үзенә генә түгел, хатыны Фәния апага да Ходай сабырлыкны мулдан биргән. Аларның мәхәббәте дә мәктәп елларында ук бөреләнә. Алар бер сыйныфта укыйлар. Мәктәптә "Асылъяр" спектаклен куйганда укытучылары аларга төп рольләрне тапшыра. Шул әсәрдәге мәхәббәт каһарманнарының хисләре яшьләрнең үзләренә дә күчә. Еллар үткәч тә ул хисләр сүрелми. Миңгол абый белән Фәния апа менә инде 40 елдан артык тормыш сукмагыннан бергә атлыйлар.

"Хатын-кыз ул – өйнең яме, йә тартып тора, йә киресенчә, читкә этәрә. Әгәр хатының каршы булса, чит кешене түгел, туганыңны да өйгә кертеп булмый. Өйләнгәндә үк аңлашып куйдык. Безнең өйдә элек-электән үк шундый гадәт иде. Ишегебез һәркем өчен ачык, һәркем өчен өстәлдә чәй, кайчан, кем белән кайтып керсәм, төнме ул, көндезме – якты йөз булырга тиеш. Ә бер-береңә ачуың килсә, кеше киткәч аңлашырга мөмкин. Аллага шөкер, ул яктан

Фәниямә рәхмәтем зур, танышларым, укучыларым очраганда да иң беренче аның хәлләрен сорашып, сәлам әйтеп җибәрәләр", - ди Миңгол абый.

Мәхәббәт җимешләре – Роза белән Марат та әти-әниләреннән үрнәк алып үсә. Роза Казан дәүләт педагогика институтын тәмамлап, укытучы һөнәрен үзләштерә, Марат авиация институтында белем алган. Кызларының гомере генә үкенечле тәмамлана. Аксубай егете Вәлигә кияүгә чыгып, ике бала алып кайта ул. Шәһәр кызы дип тормый, терлек-туар асрап, бакчасында яшелчәләрен үстереп көн итә. Тик, ни аяныч, Розаны 37 яшендә яман авыру аяктан ега, бөтен туганнарын кайгыга салып, якты дөньядан китеп бара... Әле дә ярый оныкларыбыз бар, дип сөенә бүгенге көндә Миңгол абый белән Фәния апа. Әнә шундый хәсрәт ачыларын татырга туры килсә дә, сабырлыкларын җуймыйча, язмышларына риза булып, бүгенге тормышларыннан ямь табып яшәргә тырыша алар. Гел яшьләр, балалар арасында булуы, күпкырлы иҗаты, татар моңын кайгыртып яшәве аңа картаерга ирек бирми. Ул бүген дә яңа хыял, омтылышлар белән яна. Әле тагын бик күп еллар халкыбызга хезмәт итәргә, тормыш иптәше, балалары һәм оныклары җылысын тоеп, рәхәттә яшәргә язсын аңа!

**IV. Йомгаклау**

"Мин укучыларым чыгышыннан, үзем җырлауга караганда, күбрәк ләзәтләнәм. Алар танылса, ихлас сөенәм. Эшемне дәвам итәрдәй укучылар калсын, дип тырышам", - ди укытучы-остаз. Ул, кая чакырсалар, шунда бара. Гел юлда. Җыелган халыкны рухи азыксыз калдырырга хакым юк, дип саный. Үзенә күрә бер тыйнаклык белән җырын суза, мөнәҗәтен көйли. Мөнәҗәт дигәннән, авылдашлары белән очрашу кичәләрендә Миңгол абый, әнисенең якты истәлегенә багышлап, балачак хатирәләрен яңартып, хәтер сандыгындагы мөнәҗәтләрен барлый, тыңлаучылар хөкеменә тапшыра. М.Галиев "Күңелем түзми моңланмыйча" дигән мөнәҗәтләр җыентыгын да чыгара.

Җырчы буларак, якташыбыз Сара Садыйкованы, Фәхри Насретдиновны, Габдулла Рәхимкуловны үзенең остазлары итеп саный һәм аларның иҗаты каршында түбәнчелек белән баш ия. С.Садыйкованың юбилей көннәрендә, туган авылы Иске Комазанга кайтып, композиторның тормыш юлы һәм иҗатына багышланган очрашу - кичә оештырырга да вакыт таба, яраткан җырчыларының иҗатын пропагандаларга да өлгерә. Комазан халкы Миңгол абыйның үз шәкертләре белән дә очрашып-танышып тора. Рәсим Низамов, Рөстәм Закиров кебек танылган җырчыларны студент елларыннан ук белүләре белән бәхетле авылдашлары. Җырчы һәм укытучы. Бу ике сүз бер-берсеннән аерылгысыз. "Укытучыма", "Сез иң гүзәл кеше икәнсез" кебек җырларны бәйрәмнәрдә тыңлыйбыз, әлбәттә, М.Галиев башкаруында.

Күренекле якташыбызның кешелек сыйфатлары турында да әйтеп китәргә кирәк. Аның белән якыннан таныш кешеләр һәм без, авылдашлары, Миңгол абыйның гади, ярдәмчел, масаюның нәрсә икәнен белмәгән, тырыш сәхнә йолдызы булуын беләбез. Тырышлык һәм тыйнаклык, гомумән, Галиевлар нәселенең төп сыйфатларыннан санала. Күренекле авылдашыбыз җырчы буларак та, педагог буларак та һәрвакыт эзләнүдә. М. Галиев Япония, Болгария, Румыния, Финляндия, Төркия тамашачысы каршында музыка һәм җыр сәнгате аша татар халкының дәрәҗәсен, абруен күрсәткән, Мамадыш төбәгенең, Иске комазан авылының данын бөтен дөньяга тараткан җырчы. Голландиянең күренекле композиторы М.Кейс аны "Дөньякүләм тавышлы җырчы!" – дип атаган һәм шул турыда язып та чыкты. Ул - безнең горурлыгыбыз!

*Кулланылган әдәбият*


1. Зиннурова А.З. "Авылым: аның кешеләре һәм эшләре", Казан: Мәгариф, 2004;
2. Газизов Р.Ш. Мамадышым – язмышым, Ижау: ГУП УР «Ижау республика типографиясе», 2005;
3. "Сәхнә" журналы, Казан: "ТАТМЕДИА" АҖ, №9, сентябрь, 2016.

# ҮТКӘНЕН БЕЛМӘГӘННЕҢ-КИЛӘЧӘГЕ ЮК

*Тимирова Гүзаль Ильшатовна, ученица 8 класса*
*Научный руководитель – Мухамметзянова Альбина Мавлявиевна*
*СОШ с.Маскара им. Н.А.Самигуллина*
*Кукморского муниципального района РТ*

Тарихка тирән эз салган туган авылыбыз , халкы, тормышы, архитектура истәлекләре, күренекле шәхесләре, аларның тормыш һәм хезмәт юлы, кылган батырлыклары хакында өйрәнү теләге миндә тарихны, туган якның тирән тамырлы нәселләрен хөрмәтләү, шәхесләребезнең шәҗәрәләре белән кызыксынудан туды дияр идем мин. Чөнки тирән тарихлы авылыбыз, данлы Үтәмешевлар нәселе авыл халкы горурлыгы гына түгел, ул Татарстаныбыз, илебез горурлыгы, барлык кешелек дөньясына үрнәк, чын мәгънәсендә олы исемгә лаек нәсел. " Үткәнне өйрәнми торып, бүгенгене белеп булмый" диләр бит. Менә шуннан чыгып мин авылыбыз, аның нәсел шәҗәрәсе, данлы Үтәмешевлар турында тирәнрәк эчтәлекле мәгълүматлар туплый башладым. Мәктәп музеена да мөрәҗәгать иттем.Шунысы куанычлы: авылыбыз тарихы турында язмалар, олуг Үтәмешевлар нәселе хакында бик күп материаллар музейда тупланган, аларга багышланган бүлек тә бар. Аларның нәсел шәҗәрәләре,һәм башка бик күп истәлекләре музеебызда саклана. Үтәмешевларның бүгенге буын вәкилләре мәктәбебезнең хөрмәтле кунагы булып кайта, музеебызда булып,истәлекләр белән кызыксынып, хәтирәләрен яңарталар. Фәнни эшемә төрле чыганаклардан авылыбыз тарихы, Үтәмешевлар нәселе турында, аларның хезмәт өлкәсендәге күпкырлы эшчәнлеге, кылган игелекләре турында күбрәк мәгълүмат җыеп, бу данлы шәхесләр турында язып, үземнән бераз өлеш кертү файдалы булыр дип уйлыйм.Чөнки үткәннәрне онытырга безнең хакыбыз юк.Борынгы бабаларыбыз, алар узган бормалы юллар-үзе бер тарих. Ә туган ягыбызның горурлыгы, ил язмышын үз җилкәләрендә күтәргән күренекле шәхесләребез тормышы –ул якты маяк.

*Теманың өйрәнелү дәрәҗәсе.*

Безнең Мәчкәрә авылы истәлекле,тарихи, укымышлы, күренекле шәхесләре белән дан тоткан авыл буларак, бик күп яклардан аерылып тора. Ул Ишмән иле дип йөртелгән,байларның шәкертләрнең күплеге ягыннан күренекле бер авыл булган. Мәчкәрә авылында татарлар яши башлау, Балтач районы Бөрбаш дигән авылдан Туктаргали һәм аның улы Ишмән исемле кешеләр килеп урнашу белән бәйләнгән булган.Мәктәп музеенда саклаучы шәҗәрәдә авылның тамыры нәкъ менә Туктаргалидән башлануы ачык чагылган.Әйе,Үтәмешевлар нәселе тирән тамырлы,бай нәсел, хезмәт сөючән кешеләр булганнар.

Бүгенге көндә Үтәмешевлар - балалары,оныклары үз бабаларының данлы исеменә тап төшерми, зур казанышларга ирешеп көн күрә. Җөмһүриятебез,туган ягыбыз, авылыбызның иң мәртәбәле,үзенчәлекле олуг шәхесе булып яшиләр.Танылган байлар Үтәмешевлар Ш.Мәрҗәни хезмәтендә дә искә алына. Үтәмеш Казан һәм Мәчкәрә мәчетләрен төзетүче Гали бай Үтәмешевның ерак бабасы Үтәгәннең кушаматы булган. Үтәмешевлар фамилиясе дә шуннан башланган диләр.Һәм бу фамилия бүген дә данлы,чөнки алар арасында олы галимнәр, үзләренең зур хезмәтләре белән дан казанган фән кешеләре бар.Авылыбызда архитектура истәлекләре булып саклаучы биналар, аларның бабаларының тырыш хезмәте үрнәге булып тора.Һәм алар хаклы рәвештә горурланалар. "Әгәр без борынгы бабаларыбызны онытсак, берникадәр вакыттан соң безне дә онытырлар", дигән бит халык.Бу сүзләрдә никадәр тирән мәгънә ярылып ята.Ә алар онытмыйлар, ел да саен бабаларының туган авылына, нигезләренә кайтып укучылар,авыл халкы белән очрашалар, бабаларының каберләренә барып зыярат кылалар, изге догаларын ирештерәләр.Үткәннәргә күз салсаң, авылыбызның чал тарихына, данлы шәхесләренә карата күңелдә горурлык хисләре уяна.

*Эшнең максаты.* Буыннар бәйләнеше,ядкарьләргә кызыксыну уяту,борынгы бабаларыбызның үткәне,туган ягыбызның күренекле шәхесләре белән горурлану хисләре тәрбияләү.

Шушы максатка ирешү өчен түбәндәге бурычларны башкарырга кирәк :

1.Авылыбызның тарихын, күренекле шәхесләрен барлау.

2.Үтәмешевлар нәселе шәҗәрәсен өйрәнү.

3.Туган ягыбызның күренекле шәхесләре казанышларына аңлы бәя бирү.

**1 нче бүлек. Үткәнен белмәгән халыкның - киләчәге юк.**

1. **Шәҗәрә –нәсел агачы.** . Киләчәккә аек карар. Үз тарихын анык белгән!...

Шәҗәрә-нәсел агачы дигән сүз. Шәҗәрәне белү ул һәркемнең олы, изге бурычы .Чөнки шәҗәрәләр безгә халкыбызның үткән юлын, чал тарихын сөйли. Ә нәсел тарихларын өйрәнү, ул әлбәттә гаиләдән, туганнардан, дуслардан башка башкарылып чыга торган эш түгел.Шуңа да дуслык-туганлык һәрдаим янәшә барырга тиеш. Туганлык хисләре, буыннар тарихы – ул гаилә ядкаре булып киләчәккә бара.Ә киләчәк ул яңа буын дигән сүз.Буыннар чылбыры ул бик озын.Шушы озын чылбырларда буталып калмас өчен һәркем нәсел тарихын өйрәнергә тиеш.Чөнки үз туган ягының, нәселенең тарихын ачык белгән кеше генә киләчәккә аек һәм зур өмет-ышаныч белән карый.

Безнең Мәчкәрә урта мәктәбендә урнашкан «Туган якны өйрәнү музее» нда бик кадерле, кыйммәтле экспонатларның берсе , күзгә күренеп торган иң эчтәлеклесе – ул Мәчкәрә авылы кешеләренең буыннар шәҗәрәсе бар. Шәҗәрәдә авылыбыз тарихы, аның танылган кешеләренең язмышы саклана.Ә шәҗәрәнең тамыры ныклы Үтәмешләр нәселеннән булуы,авылыбыз өчен үзе зур дәрәҗә. Шәҗәрә – чал тарихлы хәтер хәзинәсе. “Әгәр дә үлгәч искә алсыннар дисәң, игелекле нәсел һәм эчтәлекле китап язып калдыр!», - дигән борынгы акыл ияләренең берсе. Игелекле нәсел калдыр - бу сүзләр кешегә икеләтә бурыч йөкли. Беренчесе – нәселең игелекле булсын өчен, син үзең игелекле булырга тиеш. Икенчесе – игелекле балалар тәрбияләргә тиешсең. Һәм иң мөһиме,һәркемдә үткәннәр белән элемтәне югалтмау омтылышы яшәргә тиеш , чөнки үткәннәрдән башка киләчәк юк.

Хәтерләүдән курыкма син!

Үткәнеңне онытма син!Әйе, «Илен белмәгән – игелексез, халкын белмәгән – холыксыз, нәселен белмәгән – нәсәпсез» дип юкка гына әйтмәгән халкыбыз.

Адәм баласына үзенең җиде буын бабасын белү фарыз, дигәннәр борынгылар. Шул вакытта гына кеше туган иленең, туган төбәгенең, туган йортының үткәнен, үз халкының чыгышын белә. Шуның өчен дә без бүген шәҗәрәләрнең тарихын, туган авылның үткәнен белү, туган төбәкнең тарихи урыннарын хөрмәт белән саклау фарыз дибез. Чөнки шәҗәрәләр безгә халкыбызның үткән юлын, чал тарихын сөйли. Әйе, бабаларыбызны оныту зур хата булыр иде. «Үткәнен белмәгән халыкның - киләчәге юк», - дип әйткән күренекле галимебез Шиһабетдин Мәрҗани дә.

**2.Тирән тамырлы нәсел –Үтәмешевлар.**

Шәҗәрәгә кергән кешеләрне карендәшләр диләр бит. Авылыбызның нәсел тамыры ныклы, тирән булуы белән без чиксез горурланабыз.Һәм киләчәк буынга бабаларыбызның узган данлы гомерләре хакында сөйләргә тырышабыз. «Әгәр без борынгы бабаларыбызны онытсак, берникадәр вакыттан соң безне дә онытырлар». Менә шушы изге сүзләрнең тирән мәгънәсенә төшенергә тырышабыз.Бүгенге буын кешеләре,балалар олы шәхесләребез, авылыбыз горурлыгы булган Үтәмешевларның уллары, оныклары белән очрашып, аралашып яшәү бәхетенә ия.Һәм без бүген аларның олы хезмәтләрен белеп, бабаларының данлы юлын дәвам итүләре, нәсел тамырлары,шәҗәрәләре белән кызыксынып яшәүләренә сокланабыз.Әйе,хөрмәтле галим Илдар Үтәмешевның әтисе Рөстәм абыйның да тормыш юллары чуалчык булган.Ләкин ул нәселнең данлы исемен саклап калган, сынмаган-сыгылмаган.

**3. Җирдә матур эз калдырып.**

Кеше җирдә ни өчен яши? Үзенең кыска гына гомере эчендә ул барысына да өлгерә: барын да таныргa, белергә, үзе эшләп карарга, сөенергә, кайгы – хәсрәтләрне җиңеп чыгарга

һәм иң мөһиме – үзе турында киләчәк буынга якты истәлек калдырырга тырыша. Әлеге сүзләр 1926 нчы елда безнең Мәчкәрә авылында дөньяга килеп Ю.Гагаринны очышка әзерләү дәрәҗәсенә кадәр үскән галим – Үтәмешев Рөстәм Исмәгыйль улына карата әйтелгәндер, мөгаен.Үтәмешевләр гаиләсенең язмышы бик ачы була.Алар күргән михнәтләрне күз алдына китерү дә куркыныч.Әмма куәтле тамырдан:ислам динен таратуга,мәгърифәтне үстеүгә омтылган Ишмән нәселеннән булуы Рөстәм Исмәгыйль улына тормышта югалып калмаска ярдәм итә.Ул зур тырышлык куеп фән өлкәсендә хезмәт итәргә керешә. Ул Ленинград авиация приборларын төзү институтын тәмамлаганнан соң хәрби һава көчләренең фәнни - тикшеренү институтында эшли. 1967-1984 нчеелларда медицина техникасын үстерү буенча илнең баш институты белән житәкчелек итә. Үзара икътисадый ярдәмләшү Советына кергән илләрнең координацион үзәген житәкли. СССР Сәламәтлек саклау министрлыгының баш метрологы була.

1967 нче елда Ю.Гагаринны очышка уңышлы әзерләве өчен Хезмәт Кызыл байрагы ордены белән бүләкләнә. 1991 - 94 нче елларда медицина фәннәре Академиясенең квалификацияле гыйльми советы әгъзасы һәм үзе җитәкләгән институтның махсуслаштырылган Советы рәисе була. Ул 300 дән артык фәнни эш, 120 уйлап табулар авторы. Россия табигать фәннәре, медицина техника фәннәре Академияләренең мөхмир әгъзасы. Ул бик күп бүләкләр, медальләр һәм исемнәргә ия. Мәсәлән, радиотехника өлкәсендә уңышлы уйлап табуы өчен А.Попов исемендәге; “РСФСРның мактаулы уйлап табучысы”; Королев, Гагарин исемнәрендәге һ.б төрле медальләр, үлгәннән соң да аңа Хезмәт Кызыл байрагы ордены, 1 нче дәрәҗә «Вернадский йолдызы» ордены бирелә. Гомумән алганда, Рөстәм Үтәмишевның гыйльми эшчәнлеге, уйлап табу, үстерү, камилләштерүдән, беренче космонавт Ю.Гагаринны очышка әзерләү, зур фәнни ачышлары һәм хезмәтләре белән данлы.

Үтәмешев Рөстәмнең улы Илдар да олы галим - техник фәннәр докторы, академик. Ул 1954 нче елда Казанда туа. Мәскәү физика-техника институтын тәмамлаганнан соң «Квант» Бөтенсоюз фәнни-җитештерү берләшмәсендә индроскопия һәм томография өчен өч кырлы голографик сурәтләү жайланмаларын, голографик медицина җиһазларын уйлап табу, рентгенография алымнары һ.б. өстендә эшли. Медицина техникасын үстерү буенча берничә халыкара проектын җитәкли, Гамәли тикшеренүләр институтының Генераль директоры була. Ул 20 төргә якын аппаратура эшли. Россия табигать фәннәре, медицина–техника фәннәре,сәнәгать экологиясе академияләренең мөхбир әгъзасы һәм бик күп бүләкләр иясе:Бөек Петр, Вернадский медальләре, “Халыкара ел кешесе”, “Фән һәм сәнгать рыцаре” медале, 2 нче дәрәҗә “Вернадский йолдызы” ордены. Димәк, туган ягыбызның данлыклы Үтәмишевлар нәселе сәүдәгәрлек эшеннән фән өлкәсенә күчкән, чөнки заман шулай таләп итә.алар бүгенге көндә үзләренең шушы нәсел тамырыннан булулары белән бик тә горурланалар. Ә без Мәчкәрә төбәгендә яшәүчеләр, гасырлар аша буыннан – буынга изге мирас булып тапшырылып килгән искитәрлек акыл- зиһенен кешеләргә хезмәт итүгә багышлаган бу күренекле шәхесләр – олы галимнәрнең хезмәтләрен өйрәнәбез һәм хөрмәт итәбез.

**Мәчкәрә-тарихта тирән эзле авыл.**

Безнең яклар истәлекле, тарихи булуы белән күп яклардан аерылып тора. Татар халкының мәшһүр тарихчы галиме Шиһабетдин Мәрҗәни дә үзенең «Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр» дигән ике томлык хезмәтенең «Казан тирәсендә кайбер авылларның кыскача тарихы» дигән бүлегендә сүз башында «Бу фасылда нәрсәсе беләндер танылган яки берәр мөнәсәбәт белән билгеле булган Казан шәһәре тирәсендәге кайбер авылларның кыскача тарихлары һәм аларны төзүчеләр искә алына» дип яза һәм башка берничә авыл белән беррәттән, Мәчкәрә авылының тарихына да туктала. Телдән сөйләнгән бик күп истәлекләр һәм кайчандыр Оренбургта басылып чыккан Мәчкәрә авылы тарихы турындагы материалларны үзләре укыган абзыйларның сөйләүләре буенча (Шакиров Габдрахман һәм Камалов Гомәр) Мәчкәрә авылында татарлар яши башлау моннан 30 км. чамасы ераклыкта булган Бөрбаш дигән авылдан килеп утыручы Туктаргали һәм аның улы

Ишмән исемле кешеләр килеп урнашу белән бәйләнгән булган. Бу турыда музейда урнашкан нәсел шәҗәрәсе дә сөйли. Легендаларда сөйләүләргә караганда, Туктаргали Бөрбаш авылында җир аз булганлыктан, җирне күп алу исәбе белән яңа урынга күчәргә булган. Кайда күчүне билгеләү өчен Бөр елгасына йомычка агызып җибәргән һәм шул йомычка кайда тукталса шул урынга күчәргә булган. Ә ул йомычка Бөрбаш авылыннан ага башлап Мәчкәрә авылының тегермән янындагы агачлыкка кадәр агып килгән дә, шул агачлыкка җиткәч, агачларга бәрелеп тукталган. Яр буйлап атка атланып йомычка агымы буенча карап барган Туктаргали дә шул урынга күчеп утырырга булган. Туктаргали һәм Ишмән (Ишмөхәммәт) күчеп утырган вакытта бу якларда урман һәм җир күп булган. Алар килеп урнашуга, күршедәге Янгул авылында яшәгән татарлар Мәчкәрә авылына, Мәчкәрәнең хәзерге тегермән очы урамнарында яшәгән марилар Янгул авылына күчкәннәр. Мәчкәрәгә татарлар килеп утыру белән андагы удмуртларның бер төркеме күчеп киткән, ә бер төркеме татарлар белән катнашып татарлашканнар. Бу урындагы баштагы авыл исеме буенча Мәчкәрә авылы исеме сакланган. Ләкин яңа күчеп килүче Ишмән исеме белән авылны Ишменово дип йөртә башлаганнар. Бу вакыйгалар моннан 400-500 еллар элек булырга тиеш. Чөнки хәзерге Мәчкәрә зиратындагы (Ишан зираты) Фатима исемле 15 яшьлек кызга куелган кабер ташында: зиратта беренче кабер дип язылган язу (иске гарәп язмасы белән) хәзерге Мәчкәрә авылының моннан 400-500 еллар элек төзелүен раслый. Шулай итеп Мәчкәрә авылы Ишмән иле дип йөртелгән,байларның шәкертләрнең күплеге ягыннан күренекле бер авыл. Бөре башы авылыннан Ишмән бине Туктаргали бине Көчек бине Тәбеҗ исемле кеше хайваннары һәм йорт-җирләре белән авылдан читкә чыгып, башлап утар ясап урнашкан. Бераздан соң ул Бөре башында яшәүче Эшмәкә исемле Кеше белән дошманлашып, шул Эшмәкәнең җәбер һәм хурлауларына түзә алмыйча, Мәчкәрәдә урнашкан диләр. Бөре башы авылына салган мәчетен сүтеп, бүрәнә һәм агачларын хайваннарының муенына тагып Мәчкәрәгә күчергән. Бераздан соң Туймәк бине Туйкә исемле кеше ул мәчетне Бөре башы авылына яңадан кайтарып, авыл халкына һәм иманнарына биргән. Бу мәчет хәзер дә мирас юлы белән иманнан иманга күчеп килә.

Бер хәбәргә караганда Ишмәннең Гаед, Габдессәлам, Габделмәннән, Сәгыйдь, Бәшир, Нәзир, Үтәмеш исемле җиде улы булган. Икенче Бер хәбәргә караганда Ишмәннең Гаед һәм Үтәмеш исемле ике улы калган. Үтәмештән Габдессәлам, ә аннан соң Мөхәммәтрәхим һәм Габдулла туган. Үз балалары бу заманда нәселләрен «Габдулла һәм Габдессәлам бине Хәлим бине Йосыф бине Ишмән бине Туктаргали бине Көчек бине Ходыш бине Сөләйман эй-Кирмани» дип билгелиләр. Ләкин Габдессәламнең атасы Хәлим бине Йосыф булганмы әллә Йосыф бине Хәлимме икәнлегенә шөбһә бар.

Янә шунысы бар, әлеге Габдулла байның Мәчкәрәдә мелла Габделхәмид мәдрәсәдә укыган вакытта «Гыймадел – ислам» китабын үз кулы белән язып тәмамлаган. «Бу китапны Габдулла бине Габдессәлам бине Үтәмеш – Мәчкәрәдә Габделхәмид бине Үтәгән мәдрәсәсендә 1758 нче елда язды. Сүзе тәмам. Мәгәр «Үтәмеш» бабасының кушаматы булуы да мөмкин.

Шулай итеп, Шиһабетдин Мәрҗәни Мәчкәрәгә килеп урнашкан беренче татар кешесе Туктаргали Ишмөхәммәт икәнлеген хәбәр итә. Чыннан да авылның тарихы белән эчкәрәк кереп танышсаң, бу авылның мәдәниятле кешеләр өчен үзенә күрә мәртәбәле төбәк булуына ышанасың. Шиһабетдин Мәрҗәнинең бабасы мелла Мөхәммәдрәхим бине Йосыфтан белем ала.

**2.Мәчетле авыл-изге авыл.**

Мәчетле авыл - изге авыл диләр. Безнең авылдагы мәчет тә 1791 нче елны Абдулла бай тарафыннан төзетелгән. 1793 нче елда анда беренче намаз укылган. Икенче мәчет 1872 нче елда Исхак бине Габдулла тарафыннан төзетелгән. Чөнки аңа кадәрге агач мәчет янгын чыгу аркасында янып беткән. Ә ул агач мәчетне Габдулла байның малае Муса төзеткән була. Муса Мәчкәрәдә һәм Бохарада белем алганнан соң, үзлегеннән китаплар укып, олы галимнәрнең белемнәрен өйрәнгән. 1800 нче елны Мәчкәрә авылында булган мәҗүси арларны дингә кертүгә ирешә. Менә шушы вакытта ул теге агач мәчетне салдыра. Ләкин ул салдырган

мәчет, әйтеп үткәнебезчә, 1871 нче елны ут чыгып янып бетә. Һәм 1872 нче елда аның улы Исхак аның урынына таш мәчет төзетә. Хәзерге көндә ул клуб хезмәтен үти. Авылдагы атаклы байлар – Үтәмешевларның нәсел тамырлары тирән. Алар үзләрендә Вятка аръягындагы урманнарны, Мәчкәрә белән Тәмәй авыллары арасындагы болыннарны һәм Мәчкәрә тегермәне янындагы җирләрне тотканнар. Үтәмешев Вятка аръягындагы урманнарны Иске авыл алпавытына картада уйнап оттырган. Шуннан соң ул урман Иске авыл алпавытына күчкән. Мәчкәрә белән Тәмәй авыллары арасында, Бөр елгасы буенда урнашкан Кытап (тукыма) фабрикасына да Үтәмешевлар хуҗа булган. Ул фабрика Оренбургтагы гильдия купецлары өчен тукыма җитештергән. Әйләнә-тирә авыллардагы халык Үтәмешевлар фабрикасында эшләгән. Туку фабрикасы янында эрләү мануфактурасы да булган. Җеп эрләү өчен мамык Урта Азиядән китерелгән. Авыл халкының барысы да надан булган. Ике мәдрәсә булса да, анда ярлы крестьян балаларын һәм ятим балаларны укырга алмаганнар. Бу мәдрәсәләрдә хәлле кеше балалары гына укыган.

**3. Данлыклы нәсел.**

Танылган байлар Үтәмешевлар Ш.Мәрҗәни хезмәтендә дә искә алына. Үтәмеш Казан һәм Мәчкәрә мәчетләрен төзетүче Гали бай Үтәмешевның ерак бабасы Үтәгәннең кушаматы булган. Үтәмешевлар фамилиясе дә шуннан башланган. Габдулла һәм Мөхәммәдрәхим Үтәмешевларның Мәчкәрәдәге мануфактура предприятиеләре 1778 һәм 1785 нче елларда төзетелгән. Малмыж өязендә туку фабрикасы булса, Алабуга өязендә постау фабрикасы төзеткәннәр алар. Безнең мәктәп музеенда Үтәмешевларның туку фабрикасының штампеле, печате саклана. Үтәмешевларның Казан губернасында да предприятеләре булган. Мәсәлән, Мамадыш өязендә Үтәмешевларның поташ һәм бакыр эретү заводлары эшләгән. Ул вакытта Мәчкәрә авылы Вятка губернасының Малмыж өязенә кергән. Үтәмешевлар Вятка губернасында иң бай, иң танылган промышленниклардан саналганнар. Авылда Үтәмешевлар төзеткән биналар әле дә саклана. Хәзерге вакытта шуларның берсе коррекция интернат-мәктәп (ике катлы) бинасы булып тора.

**Туган авылыбыз күренекле шәхесләре белән данлы.**

Без, Мәчкәрә төбәгендә яшәүчеләр,тагын бер күренекле шәхес белән горурлана алабыз.Әлеге шәхеснең нәсел тамырлары да борынгы Мәчкәрә кешеләре буыннарына килеп тоташа.Бу дөнья әдәбияты һәм җәмәгатьчелекнең олы шәхесе Чыңгыз Айтматов нәселе. Чыңгыз Айтматов Үтәмешләр нәселенә ничек барып тоташа соң? Баксаң Чыңгызның әнисе Нәгыймә - Үтәмешевларга караган Хәмзә Габделвәлиев кызы икән.Нәсел агачында Нәгыймә Хәмзә кызына “караучы ботак” 1610 елдан хисаплана. Аның башында Туктаргали тора. Аны гади генә менә болай аңлатып булыр иде : Туктаргали – Ишмән – Йосыф – Хәлил – Габдрәшит – Гайсә – Габделвәли – Хәсән – Хәмзә (Чыңгызның бабасы). 1840 нчы елда дөньяга килгән Хәмзә Габделвәлиев тә заманының атаклы сәүдәгәре булган.

Чыңгыз аганың әнисе Абдулвәлиева Нәгыймә Хәмзә кызының нәсел тамыры нәкъ менә шушы Мәчкәрә авылында инде.1610 елда дөньяга килгән Ишмән Туктар улыннан башланган шәҗәрәдә Хәмзә исемендә тукталган Абдул-вәлиевлар тармагы да бар.Чыңгыз Айтматовның икенче буын туганы Ренат Абдулвәлиев “Алар якты эз калдырды”исемле мәкаләсендә үзләренең Ишмән нәселеннән булулары турында яза :”Чыңгызның әнисе Нәгыймә апа минем әтием Шәрифнең бертуган сеңлесе була.Кайчандыр,16 гасыр уртасында ук безнең бабаларыбыз хәзерге Татарстан территориясенең Мәчкәрә авылына (Кукмара районы) нигез салганнар,19 гасырның 70 нче еллар азагында Хәмзә бабай –туганнары Әхмәтгали һәм Галия белән туган якларны ташлап, кәрәванга ияреп ,Урта Азиягә китәләр”. Каракүл шәһәрендә Хәмзә белән аның хатыны Газизәбануның 8 баласы туа. Алар: Мөхәммәтҗан, Сабир, Шәриф, Габдулла, Гөлшат, Нәгыймә, Әсмәбикә , Зиннәт.

8 баланың берсе - Нәгыймә Габделвәлиева – Чыңгыз Айтматовның әнисе. Хәмзә кызы Нәгыймәне бик яраткан.Хәмзәнең сөекле кызы Нәгыймә Төрекул Айтматовка кияүгә чыга. Ул Кыргызстан партия өлкә комитетының агитация һәм пропаганда бүлеге мөдире була.

Нәгыймә апа, ире репрессиягә эләгеп, ачы язмышка дучар булып, балаларын ялгыз үстерә. (Айтматовлар гаиләсе турында үзебезнең район газетасы “Хезмәт даны”нда 2006

ел,25 март санында басылган Р.Закированың “Чыңгыз Айтматов:“Безнең өчен изге урын”дигән язмасында ачык язылган). Ата улны, ана кызны онытырга тиеш булган куркыныч бу заманда исән калу өчен күпләр үзләренең нинди нәселдән булуларын яшерергә мәҗбүр булганнар. Нәгыймә апа, мөгаен, соңгы көннәрендә сер пәрдәсен ача төшкәндер: ата-бабаларының туган туфрагына кайтып егылу турында хыялланган ул, әмма ерак юлга чыга алырлык хәлдә булмаган. Бөек язучы “Анам кыры” әсәрен – аларны, ягъни 4 ятимне тәрбияләп үстергән әнисенә багышлый. Кыргыз язучысы Чыңгыз Айтматовның Мәчкәрә авылына - әнисенең ата-бабалары яшәгән изге төбәккә кайту теләге көчле булган. Ләкин рәхимсез үлем әдипкә бу төбәккә кайтып җитәргә аяк чалды шул. Авылда Чыңгыз аганың туган-тумачасын хәтерләүче өлкән яшьтәге Сәрвәр әби бар иде. Ул гомере буе шушы авылда яшәгән кеше. Һәм ул болай дип сөйли торган булган: ”Нишләп яшьрәк чагында кайтып китмәде икән ул Чыңгыз. Бабаларының каберен дә, яшәгән җирләрен дә күрә алмый үлеп китте бит, бахыркай. Аларның нәселләре бик әйбәт иде. Халыкка ярдәм итеп тордылар. Әнә,”Мөхәммәдия”мәдрәсәсенең өченче катын да алар салдырган, Россиядәге күп кенә мәчетләр алар тырышлыгы белән төзелгән. Безнең авылда да бик яхшы мәдрәсә бар иде. Заманында анда бик танылган кешеләр укыган, чит төбәкләрдән дә килеп белем эстәгәннәр”. Әйе, зур гына алмагач бакчасы, күле булган, бик матур өйдә шулар нәселеннән чыккан аганың яшәгәнен хәтерли иде Сәрвәр апа. Шулай Чыңгыз ага гомере буе әнисенең нәсел җебен беләсе килеп яшәгән. Ә Нәгыймә Хәмзә кызы Айтматова, туган җирен сагынып, бик күрәсе килеп, 1971 елда 66 яшендә вафат була.Мәчкәрәне кайтып күрү насыйп булмый аңа. Сәламәтлеге какшау сәбәпле юлга чыгарлык хәлдә булмый ул.Нәгыймә апа турында калган язмалар да истәлекле: барысы да аның сабыр, изге, игелекле зат булганлыгын сөйли. Әйе, кызганыч ул заманнарда исән калу өчен зыялылар нәселләрен яшереп килгәннәр. Күрәсең , Нәгыймә ханым да, соңгы көннәренә кадәр бу серне чишмәгән. Чыңгыз Айтматовның бүгенге көндә исән-имин булган икенче буын туганы - Ренат Габделвәлиев Кыргызстанның Бишкәк шәһәрендә яши. Аның әтисе Шәриф – Нәгыймә белән апалы- энеле бертуганнар булганнар.

Бөтен дөнья әдәбиятында танылган әдип,актив җәмәгать эшлеклесе Чыңгыз Айтматов зур мирас - кабатланмас әсәрләрен калдырып китте. Алай гына да түгел, авылыбыз өчен никадәр зур дан-дәрәҗә калдырды ул. Авылыбыз халкы тирән тамырлы бу нәсел белән чын күңелдән горурлана. Шәҗәрәдә Үтәмешевлар нәселе белән бәйле шундый күренекле кешеләрнең нәсел тармагының булуы киләчәк буын өчен якты маяк булып тора.

**Фәнни –эзләнү эшен практик яктан ныгыту.**

**”Туган якны өйрәнү”түгәрәгенә йөрүче укучылардан сораштыру уздыру.”Сорау-җавап”.**

Мин 4 нче сыйныфларда туган як темасына карата сораштыру уздырдым. “Сорау-җавап” формасында узган бу әңгәмә барышында “Туган якны өйрәнү” түгәрәгенә йөрүче укучыларның үзебезнең авыл турында, аның тарихы турында уңай гына белүләре аңлашылды. 12 укучы катнашты.

Сораулар: 1.Безнең авылга нигез салучы кеше –ул кем? Ни өчен безнең авылга килеп урнашырга булган?

2.Авылның исеме кайдан килеп чыккан?

3.Авылда нинди архитектура истәлекләре сакланган? Алар ничек атала?

4.Алар кайчан һәм кем тарафыннан төзелгән?

5.Авылыбызның күренекле шәхесләре-алар кемнәр?

6.Юрий Гагаринны очышка әзерләгән галим, туган авылыбыз горурлыгы.

7.Чыңгыз Айтматов-ул кем?

8.Авылыбызда нинди табигать һәйкәлләре бар?

9.Безнең авылдагы елганың атамасы ничек? Элек аның кырыенда нинди тегермән булган?

10.Безнең мәктәп музее ничек атала? Җитәкчесе кем?

**2.Эшкә нәтиҗә ясау.**

Укучылар чыннан да туган ягыбыз, аның тарихы, табигатенә карата битараф түгелләр икән, җавапсыз калган укучылар юк. Димәк , авылыбыз тарихы белән кызыксыналар дигән сүз. Бу әлбәттә , түгәраккә йөрүнең дә нәтиҗәседер.

**Сорау-җавап нәтиҗәләре:**

87% укучы-тулы җавап биргән.

11%- кайбер сорауларга тулы җавап биреп бетермәгән.

2% укучы- кайбер сорауларга җавап бирмәгән.

*Йомгаклау. Авылыбыз тарихының якты маяклары*.

Йомгаклап шуны әйтәсем килә, фәнни-эзләнү эшем барышында мин фәнни әдәбият белән таныштым, музейда, китапханәдә эшләргә өйрәндем; авылыбызның өлкән кешеләре белән авылыбызның тарихы турында , күренекле шәхесләре хакында әңгәмәләр кордым, язмаларны редакцияләдем, фотоларга төшердем, презентация ясадым. Түгәраккә йөрүче укучылар белән сораштыру үткәрдем. Шушы эзләнү эшем белән мин авылым тарихын, авылыбызның данлыклы шәхесләре турында өйрәнүгә үз өлешемне кертергә тырыштым.

Үтәмешевлар – бик атаклы нәсел. Әмма афәтле еллар- революция әлеге нә-селне шулкадәр тарката ки, ата-улны, ана – кызны белмәс дәрәҗәгә җиткерә. Алар бер-берсен “онытырга”, хәл белешмәскә һәм күрешмәскә мәҗбүр булалар. Ләкин болганчык еллар уза. Дөреслек өскә калкып чыга.Менә шуннан соң бу данлы шәхесләр үз нәселләрен барларга һәм Татарстанга кайту бәхетенә ирешәләр. Үз нәсел шәҗәрәләрен туган якларында табу зур шатлык китерә аларга. Мәктәбебез музеенда урнашкан Мәчкәрә авылы кешеләренең нәсел шәҗәрәсе- менә шул тирән тамырлы нәселдән башлана да инде. Бу искиткеч әһәмиятле тарихи документ. Шушы олы хезмәтне Мәчкәрә авылы укытучысы Гомәр абый Камалов башкарган.Үтәмешевлар нәселенең буыннан-буынга күчеп килгән бу ядкарь-истәлеге көннәрдән бер көнне Гомәр ага кулына килеп керә. Аңа аны бабасы биреп калдыра,кадерләп сакларга куша.Аның бабасы сәүдәгәр Үтәмешевларның ышанычлы хезмәткәре була. Ягъни сәүдә эшендә ул аларның “уң куллары”була. Мондый шәҗәрәләрне даирәле кешеләр генә эшләгән.Бу нәсел шәҗәрәсе, туганлык язмасын алар ышаныч белән шушы бабайга тапшырганнар.Ә ул үз чиратында аны гомеренең соңгы көненә кадәр саклап торткан һәм үз улына тапшырып калдырган. Шәҗәрә шулай буыннан-буынга сакланып күчеп килгән. Ә Гомәр ага аны картаймыш көнендә бик яхшылап өйрәнеп, яңадан тулыландырып күчермәсен ясаган. Аңа уллары Раиф белән Рамил булышкан. Рәсем-сәнгатькә гашыйк егетләр, әлбәттә зур кызыксыну белән әтиләренә ярдәм иткәннәр.Шәҗәрәнең ничек алар кулына килеп эләккәнен ,без Гомәр аганың кызы Рәсимә ападан (ул безнең мәктәптә укытучы булып эшләгән иде) сорашып белдек. Шәҗәрә Гомәр абыйның тырышлыгы, тынгысызлыгы, авыл халкының данлы нәсел тамырын юкка чыгарасы килмәү теләге аркасында төзелә. Ә бит Гомәр абыйның нәсел җепләре очы шулай ук Үтәмешләргә,Чыңгыз Айтматовның бабасы Хәмзәгә килеп тоташа икән ләбаса.Гомәр абый Камалов үзенең картлык көнендә зур тарихи эш эшләп, киләчәк буынга күпме зур тәрбия орлыклары биреп калдыра. Ә аның рәссам улы – Раиф Камалов авылыбыз тарихын тасвирлаган күпме иҗат җимешләрен - картиналарын истәлек итеп мәктәп музеена тапшырып калдырды. Бу картиналар үзе бер авылыбызның үткәнен чагылдыручы тарихи дөнья. Искиткеч ядкарь булып музеебызда саклананалар. Бүгенге буын кешеләре бу олы йөрәкле, изге күңелле авылдашларыбыз хезмәте алдында баш иyләр, горурлананалар.Ә Үтәмешләр нәселенең бөек шәхес Чыңгыз Айтматов белән бәйләнгән булуы икеләтә горурлык өсти.Үткәннәргә күз салсаң чал тарихлы авылыбызга, аның дәрәҗәле халкына, данлы,сәләтле,мәгърифәтле шәхесләренә карата горурлану катыш кызыксыну хисләре уяна.

*Кулланылган әдәбият:*


1.”Мәгариф” журналы: №9,2010,№12, №9 2011, №7,2004;

2.”Хезмәт даны” район газетасы : 2 июнь 2006 ел , 25 март 2006 ел, 5 сентябрь 2008 ел ;

3.”Аргументы и факты” (“Регион”) №30, 2008 ел;

4.”Татарстан яшьләре”газетасы 14 март 2009 ел ;
5.”Воспоминание о Рустаме” ,И.Р.Утямышев;
6.”Акчарлак”, 2010 ел №51-52, 2011 ел №1-3 ;
7.Музей материаллары: ”Мәчкәрә авылы тарихы”, Мәчкәрә авылы кешеләре шәҗәрәсе”, Үтәмешевлар нәселенә багышланган альбомнар, язмалар, газета материаллары, истәлекләр.

## ИСКЕ КОМАЗАН АВЫЛЫ ТАРИХЫ

*Хазиева Айгуль Миннулловна, ученица 10 класса*
*Научный руководитель – Васильева Алина Альбертовна*
*МБОУ “Дюсьметьевская СОШ”, Мамдышского муниципального района РТ*

Гүзәл табигать кочагында

Туган авылым- Комазаным...

**Вахит Галиев**

Туган як! Туган җир! Туган туфрак! Туган төбәк! Һәрбер кеше өчен нинди газиз, тирән мәгънәле сүзләр! Алар һәркем йөрәгендә яши һәм вакытлар үтү белән тагын да байый, тулылана, ачыграк төс ала бара. Туган якның бай тарихы һәм культурасы, табигате һәм көнкүреше-болар барысы да кече яшьтән үк балалар тормышының бер кисәгенә әверелә. Безнең аңыбызда һәм тойгыларыбызда чагылган таныш урыннар, акрынлап Ватан образын күзалларга ярдәм итә. Туган якны өйрәнү халык культурасының гасырлардан килгән традицияләрен, халыкның зур һәм матур эшләренә хөрмәт хисләре тәрбияләүдә туган якны өйрәнүнең мөмкинлекләре аеруча зур.

Минем дә киләчәк буын өчен игелекле эш башкарасым килде һәм, иң кулае дип, фәнни-эзләнү эше язуны сайладым. Илһам чыганагы, яшәргә көч һәм дәрт бирүче күңел маягы булган туган авылыбыз тарихы турында язганда баштан төрле уйлар кичте. Шуларны башкалар күңеленә дә җиткерәсем килә. Туган төбәк тарихын өйрәнгән вакытта, мин тагын бер нәрсәне аңладым. Бары тик туган як, гаилә, урам, авыл, мәктәп, халкың тарихларын белсәң генә, Бөтендөнья һәм Ватан тарихын тиешле дәрәҗәдә үзләштерергә мөмкин. Ә безнең авыл тарихы турында белешмәләр юк дип әйтерлек.

Туган нигез, гаилә һәм төбәк тарихын өйрәнеп, андагы горурланырлык вакыйгаларны, күренешләрне җентекләп тикшереп кенә үзеңдә патриотик гражданлык хисе тәрбияләргә мөмкин дип уйлыйм.

Шулай итеп, эзләнү-тикшеренү эшемнең **максаты** - Мамадыш районы Иске Комазан авылының тарихын өйрәнү, авылдашларымда туган төбәгебезгә карата кызыксыну уяту. Шул максаттан чыгып, эшемдә түбәндәге **бурычлар**ны үтәргә уйладым.

1) Иске Комазан авылының барлыкка килү тарихын ачыклау;
2) Авыл тарихында халкының горурлыгы булган таулар, изге чишмәләрне һәм шулай ук мәктәп тарихын өйрәнү.

Эш барышында мин түбәндәге эзләнү-тикшеренү **алымнар**ын кулландым:

1) авыл аксакаллары истәлекләре, авылдашыбыз Галиев Вахит Хәйрулла улы тарафыннан эшләнгән Иске Комазан авылының тарихы белән танышу;
2) Якташлар язмаларын, әдипләр китапларын уку;
3) "Нократ” район газетасы материалларын өйрәнү.

Куелган максат һәм бурычлардан чыгып, эшемне шундый **план**да төзедем. Ул кереш, төп һәм йомгаклау өлешләреннән, кулланылган әдәбият исемлегеннән тора.

**Төп өлеш**

**1. Авылның барлыкка килү тарихы**

Минем туган авылым Иске Комазан. Русча исеме - Старый Кумазан. Авылның исеме үзгәрмәгән, официаль булмаган исеме юк.Хәзерге вакытта Иске Комазан авылы Мамадыш районы Дүсмәт жирлеге со-ставына керә. Элек Казан губернасы, Мамадыш кантонына кергән. Иске Комазан авылы район үзәге Мамадыштан 15 чакрым ераклыкта, Мамадыш - Кукмара юлы өстендә кала. Авыл чокырда, кечкенә таучыклар арасында урнашкан. Тирә-ягын катнаш урманнар чолгап алганВ.

Нократ елгасына таба 7-8 чакрым ераклыкта Яңа Комазан авылы бар. Шуңа күрә, исемнәреннән чыгып, Иске Комазан авылына беренче нигез салганнар, дип уйларга була. Авылның нигезләнү вакыты билгеле түгел. Ләкин аның исеме килеп чыгуы турында ике легенда бар.

Мамадыштан Кукмарага баручылар чиста комлы урында Азан әйтеп китәләр" Комда азан " дигәннән Комазан килеп чыккан. Элек авыл янында ком чыгару урыны булган. Бу урынны "Ком Казаны " дип йөрткәннәр. " Ком казаны " кыскарып, авыл исеме Комазан килеп чыккан.

Иске Комазанда татар һәм керәшен татарлары бүленеше юк. Ләкин, байтак кына татар һәм керәшен кушылган яшь гаиләләр бар.

Иске Комазан авылында истәлекле урыннар да бар."Кызыл йорт", "Бакыр ширбе", "Крестьян йөрәге", "Биге юлы", "Морза очы" кебек атамалар авылыбызның тарихына бәйле рәвештә килеп чыкканнар.

Авылыбызда туып-үскән, бүгенге көндә илебезнең торле почмакларында яшәп, Туган илебезгә армый-талмый хезмәт итүче күренекле шәхесләр дэ бар. Вахит Галиев - ТРның атказанган мәдәният хезмәткәре, шагыйрь, 9 китап авторы, Мамадыш районыныц Аксакаллар шурасы рәисе, сугыш һәм хезмәт ветераны. Гарәфи Әгъләмов - шагыйрь, 2 китап авторы, Алабуга шәһәрендә яшәп ижат , итэ. Мингол Галиев - Татарстанның, халык артисты, җырчы, КДПУ доценты, татар моңнарын бөтен дөнья халкына ишеттергән милләтпәрвәр. Дусил Касыймов - Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театрында эшли, Татарстанның атказанган артисты. Авылдашларыбыз арасында күренекле сәнгать әһелләре, атказанган төзүчеләр, урманчылар, табиблар, укытучылар, орден-медальләргә лаек булган механизаторларыбыз, терлекчеләребезнең дә булуы белән мин чын күңелдән горурланам.

Иске Комазан авылында зур елгалар юк. Чишмәләрдән агып чыккан сулар җыелып ага торган кечкенә: Шуат, Чаллы, Морза инешләре бар. Шушы инешләр Комазаннан Нократка агучы Комазан елгасын тәшкил итәләр. Берничә кеше исеме белән атала торган чишмәләр бар.

**2.Чишмэлэр тарихыннан. «Изгелэр чишмэсе»**

Татар авылларының күбесендә Изге исем белән аталган чишмәләр, елгалар күп.Изге чишмәләр, ерак заманнар истәлеге булып, хәзерге көннәргә кадәр килеп җиткәннәр. Безнең татар халкы гомер буе суга табынганнар, алар чишмә буйларын чистартып, яннарына агач утыртып, буралар корганнар. Судан башка дөньяда яшәү мөмкин түгел, шуңа да халык аны изге дәрәҗәсенә күтәргән. Әби-бабаларыбыз янында коръән, намаз укыганнар. Мөселман дине тотучы кешеләр өчен иң кадерле китап Коръәндә дә чишмәләр телгә алына. Халыкта элек-электән су-чишмә, изге чишмәләр белән бәйле.Безнең Иске Комазан авылында да чишмәләр бик күп. Изгеләр чишмәсе текә яр астыннан агып чыга. Чишмә тирәсе табигатьнең гаҗәеп матур урыны: өске өлешендә бик матур урман сузылып киткән, кояш чыгышына агучы "Изгеләр чишмәсе" бу урында кинәт бормалы-бормалы агышы белән дәвам итә. Ерак түгел наратлык әйләндереп алган. Гомумән бу чишмә белән безнең авыл кешеләре озак еллар файдаланганнар һәм сокланып туя алмаганнар. Хәзер дә, әби-бабайлар изге чишмәнең суын эчеп, бит-кулларын юып, тәннәренә сафлык, чисталык алганнар. Коръән укып хәер-

сәдакаларын калдырып китәләр. Чишмә янындагы хәтфәдәй яшел чирәмгә утырып үзләренең матур теләкләрен телиләр. Төрле авырулар белән авырганда, изгеләр чишмәсеннән еракларда килгән кешеләр саф чишмә суын алып китәләр. Изгеләр чишмәсе күп санлы : чишмәләрдән, суының салкынлыгы һәм тәме белән аерылып тора. Урманнан, яки басудан арып-талып эштән кайтучы авыл халкыбыз, җәйге көннәрдә чишмә янында хәл җыярга тукталалар, суын эчәләр. Җәйләрен кызарып кояш батканда изгеләр чишмәсе өстенә кып-кызыл булып кояш нурлары төшә, су өстендә үзенә бер сихри дөнья ачыла. Бер карап сокланып торган әби-бабайларның исләренә күп еллар булган тарихи көннәр исләренә төшәдер кебек, чөнки изгеләр чишмәсе ага башлавына күп гасырлар үткән. Ул бик күп вакыйгаларның шаһиты булган. 1552 нче елларда Иван Грозный оештыру өчен тәре походы ясаган. Иван Грозный татар авылларын чукындырып йөргән, ул Дүсмәт, Комазан башы авылларын чукындырган, ә Акман авылына керә алмаган, чөнки бөтен җирдә дә су була, алар су аша чыга алмаганнар. Иске Комазан авылына якын бер авыл бар, ул элек Алкин авылы дип аталган. Алкин авылында Алкин исемле бер бай була, аның килеп чыгышы шул байдан була. Ул байның фамилиясе Алкин булган.

Бу сугыш булган җирдә кешеләр бик күп үләләр, авылдагы зират бу урыннан бик ерак, шунлыктан үлгән кешеләрне дәхшәтле сугыш булган урында гына җирлиләр. Хәзерге вакытта бу жир кадерсезләнеп ята, бу урынны кешеләр киртә белән әйлән-дереп алмаганнар, шуңа күрә, ул изге ата-бабалар җирен онытканнар. Еллар үтә, бу урын күзгә күренеп юкка чыга, булган каберлекләр иңә бара. Сонынннан бу җирне кешеләр сукалый башлыйлар.

Кешеләрнең бу изге урыннарны сакламаулары, борынгы бабаларга хөрмәтле булмау шуннан күренә. Киләчәк буын изге җирләрне белми үсә, ата-бабаларга хөрмәт уты сүнгәннән-сүнә бара. Хәзерге вакытта изге җирләр генә түгел, ә татар йолалары да онытылып бара. 1552 нче елларда Иван Грозный оештыру өчен тәре походы ясаган. Иван Грозный та-тар авылларын чукындырып йөргән, ул Дүсмәт, Комазан башы авылларын чукындыр-ган, ә Акман авылына керә алмаган, чөнки бөтен җирдә дә су була, алар су аша чы-га алмаганнар. Иске Комазан авылына якын бер авыл бар, ул элек Алкин авылы дип аталган. Алкин авылында Алкин исемле бер бай була, аның килеп чыгышы шул байдан була. Ул байның фамилиясе Алкин булган.

Кешеләрнең бу изге урыннарны сакламаулары, борынгы бабаларга хөрмәтле бул-мау шуннан күренә. Киләчәк буын изге җирләрне белми үсә, ата-бабаларга хөрмәт уты сүнгәннән-сүнә бара. Хәзерге вакытта изге җирләр генә түгел, ә татар йолалары да онытылып бара.

**3.Таулар**.

Шулай ук авылны чолгап алган тучыклар да исемлэнгэн.Авылнын кояш чыга торган ягында урнашкангамы авылнын ун ягында урнашкан тауны Кашка тау дип йортэлэр.Икенче тау исеме-Кашшаф тавы.Тау итэгендэ элек Кашшаф исемле кеше яшэгэн.Ул мал-туарын шул тауга чыгарып,котеп йоргэн,гомеренен куп вакыты тау белэн бэйлэнгэн.

**4.Әби- патша юлы.**

Иске Комазан юллары аша әби-бабайлар сөйләвенчә, Әби-Патша юлы уза. Бу таш юл әби-патша заманында төзелә башланган була. Казаннан Кукмара аша Мамадышка 7-8 чакрым җитәрәк тезелеп бетмичә туктап калган. Хәзерге көндә асфальлт астында күмелеп калган. Авылыбызның иген басуларының берсе "Кристиән йөрәге " дип йөртелә. Ул ике ягыннан чишмә агып чыккан йөрәк формасында таучык - басу. Бу җирдә иген уңмаган. Ундырышсыз җир булганга аны крестьяннарга өләшкәннәр. Табигый хэм тарихи истэлекле урыннары. Комазан төбәге истәлекле урыннарга бик бай булмаса да, һәрбер атама, һәрбер исем үзе бер тарихны хәтерләтә.

Төбәктәге тирә - якка билгеле булган "Изгеләр чишмәсе" үзе бер тарих. Татар авылларында татарларны көчләп чукындыру башлангач, патша эмиссарларына каршы, авылның батыр уллары авыл читенә көрәшкә чыга. Патша гәскәре авылга керә алмый Һәм Дүсмәт ягына юнәлә. Шушы урында бик күп кан коела. Зират ерак : булганлыктан,

үлүчеләрне шул урында гына җирлиләр. Халык бу урынны Изгеләр зираты дип йөртә башлый.

Иске Комазан авылы чокырда урнашкан һәм аны әйләндереп алган тау кырыйларына 70 елларда нарат үсентеләре утыртыла. Бу эшләрне башлап йөрүче һәм саклап үстерүче Шәмси абый булды. Хәзерге вакытта бу наратлыклар авылыбызның иң матур, истәлекле урыны. Авыл халкы аны "Шәмси урманнары" дип йөртә. Мәктәп тарихында якты эз калдырган өлкән буын җитәкчеләр ҺӘМ укытучылар бүген дә халык күңелендә. Иске Комазан мәктәбенең иң беренче директоры Хәмит Хәбибуллин дигән кеше була. Аннан соң Заһир Галимов, Мәхмүт Васыйлов абыйлар мәктәп белән җитәкчелек итүне дәвам итәләр. Бүгенге көндә бу шәхесләр исән түгелләр. Алар укыткан балалар бүген инде үзләре әби-бабайлар, әле дә булса мәктәп директорлары турында яратып һәм сагынып сөйлиләр. "Беренче карлыгачларга" алмашка килгән директорлардан Хафиз Гыйззәтуллин, Назиф Шәрифҗановлар - бүгенге көндә лаеклы ялда, Разин Вилданов педагогик эшчәнлеген дәвам итә. Урта буын директорлардан Равил Шәвәлиев ҺӘМ Салихҗан Вагыйзовлар (алар мәрхүмнәр!) да - мәктәбебезне үстерүгә күп көч куйган шәхесләр. Соңгы елларда директор Вазыйфаларын башкарган Хаҗип Ибраһимов әле дә сафта: яшь буынга белем ҺӘМ тәрбия бирү белән мәшгуль.

**5.Иске Комазан авылы мәктәбе тарихы**.

1981 нче ел мәктәп тарихында гына түгел, ә бәлки бөтен авыл күләмендә зур вакыйга белән билгеләнеп үтелә: заман таләпләренә җавап бирә торган, яхшылап җиьазландырылган өр-яңа мәктәп бинасы калкып чыга.

Яңа мәктәп бинасын сафка бастыруда шул вакыттагы мәктәп директоры Вагыйзов С. М. ның хезмәте әйтеп бетергесез зур була. Төзелеш материаллары артыннан йөрү аңа бик күп йокысыз төннәр, мәшәкатьле көннәр алып килә. Алдагы елларда мәктәпне бизәүгә күп көч куйган мәктәп коллективы белән Шәвәлиев Р. Н. җитәкчелек итә. Мәктәп өчен янып-көеп йөргән, тынгы белмәс бу директорны әле һаман да сагынып сөйлиләр.

Иске Комазан мәктәбе бигрәк тә соңгы 8-9 ел эчендә уңай якка күп үзгәрешләр кичерде. Материаль-техник база яңартылды. Мәктәбебезнең даны еракларга таралуда, иң беренче чиратта, директор Ибраиимов М. Ш. ның роле гаять дәрәҗәдә зур булды. Республика күләмендәге "Ел мәктәбе" бәйгеләрендә катнашу хокукы яулау һәм призлы урыннарга (1996 ел - 3 нче урын, 2004 ел - 2 нче урын) лаек булу - шуның ачык мисалы. Укыту-тәрбия процессы белән бәйле башка төрле конкурсларда да сынатмады мәктәп. Елның-елында мәктәп бакчасында үстерелгән мул уңыш та сөенечле нәтиҗәләрне бирә: район күләмендәге ярышларда *гел алдынгы урыннарга ирешәләр.*

**Йомгаклау.**

Тарихи төбәкне өйрәнү һәм аның тарихын язу-энә белән кое казуга тиң.Авылның үткәне турында язма чыганаклар юк диярлек, чөнки аларны язып баручы булмаган. Бердәнбер чыганак - өлкән яшьтәгеләрнең истәлекләре, буыннан –буынга сөйләнеп килгән хатирә, вакыйга, бәет, мөнәҗәт, риваятьләр. Матди чыганаклар юкка чыгып беткән диярлек. Барлык туплаган материалларны туплап без кыскача туган як тарихын өйрәнергә тиеш. Бәлки бу тарих тулысынча да булмас, әмма кайбер архивларда сакланган материаллар, өлкәннәр сөйләме, энциклопедия материаллары безгә план нигезендә үзебезне борчыган сорауларга җавап табарга ярдәм итәчәк. Тарихи төбәкне өйрәнгәнгәндә авыл атамаларына да игътибар итмичә мөмкин түгел. Алар безгә борынгы бабаларыбызның тормыш – көнкүреше, һөнәрләре гореф – гадәтләре, тарихы, теле, төбәкнең табигате, географик үзенчәлекләре, авыл халкының этник составы , кәсебе , булып узган вакыйгалар һәм башкалар турында мөһим мәгълүматлар бирә.

Халык педагогикасына кагылышлы материаллар: авылдагы йолалар, гореф-гадәтләр, бәйрәмнәр, традицияләр, мәзәкләр киләчәктә безгә үткәнебезне ныграк аңларга ярдәм итәчәк, милләтебезнең сафлыгына, әхлагына йогынтысы тиячәк.

Киләчәктә дә мин бу тикшерү-эзләнү эшен дәвам итәргә уйлыйм, тагын да тулыландыра алырмын дип ышанып калам.

*Кулланылган әдәбият*
1. Дүсмәт урта гомуми белем бирү мәктәбенең “Туган якны өйрәнү музее” материаллары
2. “Нократ” газетасы
3. Авылда һәм авылдан читтә яшәүче өлкән буын кешеләре сөйләмнәре

## КАМИЛ САТТАРОВ - ӘТНӘ РАЙОНЫ ЮГАРЫ СӘРДӘ АВЫЛЫ БЕЛӘН БӘЙЛЕ ЗУР ШӘХЕС

*Хайруллина Ирка Раиловна, ученица 4 класса*
*Научный руководитель – Хуснетдинова Гульнур Ахатовна,*
МБОУ "Большеменгерская ООШ" Атнинского района РТ

1935 нче елның 7 нче декабрендә Казан шәһәрендә Зиннәтулла абый белән Хәдичә апаның уллары Камил Саттаров дөньяга килгән. Алар гаиләдә ун бала үскәннәр. Камил абыйның тормыш юлы минем авылым белән тыгыз бәйләнгән. Зиннәтулла абый белән Хәдичә апа Әтнә районы Югары Сәрдә авылыннан. Әтисенең бабасы Мөхәммәди Югары Сәрдә авылында волость старостасы булып торган. Мортаза бабасының нигезен яхшы хәтерли Камил ага. Чөнки 1941 нче елны әтиләре Камилне һәм энесе Шамилне шәһәрдән Югары Сәрдәгә кайтарып куя. Үзе Бөек Ватан сугышына китә. Биш ел малайлар әби-бабайсында тәрбияләнәләр. Кечкенә Камил Югары Сәрдә мәктәбенә беренче сыйныфка укырга керә, биредә ике ел сабак тыңлый.

Сугыш бетә. 1946 нчы елны әтиләре авылдан шәһәргә алып киткәч, Камил Саттаров барлык туганнары кебек Карл Маркс урамындагы 18 нче татар мәктәбендә белем ала. Туган телендә белем алу аңа киләчәктә зур мөмкинлекләр ача. Гаиләдәге ун баланың сигезе югары белем ала.

Урта мәктәпне тәмамлагач, 1950 елларда Камил Саттаров Хәрби комиссариат тәкъдиме белән Ташкент шәһәрендәге СССР Эчке эшләр министрлыгы училищесына укырга керә. Аннан лейтенант исеме алып Казанга эшкә кайта. Әлбәттә, булачак җитәкче һәм режиссер өчен бу искиткеч зур белем учагы була, чөнки милиция мәктәбендә кеше психологиясе, адәми затның рухи халәтен аңлау сабагы нык бирелә, кеше белән эш йөртү юллары өйрәнелә.

Шуннан Камил Саттаров Казан шәһәренең 5 нче номерлы профессиональ-техник училищесында ел ярым белем ала. Хезмәт юлын Казан моторлар җитештерү берләшмәсендә слесарь булып башлап җибәрә. Көче-гайрәте ташып торган егетнең фотосурәте Мактау тактасына бик еш куела. Тора-бара эшчән егетне “өстә” дә күреп алалар. Камил абый комсомолның, КПССның шәһәр комитетларында инструктор, профсоюзларның Татарстан өлкә Советы инструкторы һәм өлкән инструкторы булып эш тәҗрибәсе туплый. Шушы елларда ул Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетын тәмамлый.

Очкынланып янып торган кара күзле, җитез хәрәкәтле, йөгерек акыллы бу егетнең янә бер сәләте ачыла. Камил абый “театр уйнауга”, артистлык һөнәренә бик һәвәс булып чыга. Моның өчен алшартлары да әллә кайчан әзерләнгән: Камил абый яшәгән йортка ул бәләкәй чакта ук композитор Салих Сәйдәшев, режиссер Сөләйман Вәлиев-Сульва, артист Мәрьям Сульва килеп йөриләр. Татар театрының нигез ташларын ныгыткан бу фидакарь сәнгатькярләр белән очрашулар, әңгәмәләр, әлбәттә инде, кечкенә балада театр дигән гаҗәеп серле дөньяга карата зур мәхәббәт уята. Яшьтән үк сәнгать, җыр һәм музыка яратып үсә. Мәктәптә укыган вакытта ук Камил абый татар радиосыннан тапшырыла торган инсценировкаларда катнаша, мәктәптә уздырыла торган кичәләрдә шигырьләр сөйләп күпләрне сокландыра. Аның укытучысы Асия Хәйруллина радиоспектакльләр өчен малайлар җыя. Шунда аңа “Караборын” спектаклендә төп роль – Караборын ролен бирә. Ә

Камил абый радиода өч мәртәбә эт булып өрергә тиеш. “Ишегалды саен этләр бар, шуларның ничегрәк итеп өргәнен отып алырга кирәк. Эт булып өрергә шундый остардым: алар миңа җавап бирә башлады. Шулай караборыннар арасында “үз кеше” гә әйләндем”, - дип шаяртып сөйли Камил абый. Шул вакытта аңа сәхнә җене кагылган да инде.

Күңел түрендә театр сәнгатенә туган мәхәббәт Камил Саттаровны Максим Горький исемендәге мәдәният йортының татар театр коллективына алып килә.

Режиссер Кәрим Морзаханов аңа драматург Гамир Насрыйның “Хат ташучы” комедиясендәге рәссам Азат ролен тапшыра. Сәләтенең тәүге чаткыларын шунда күрсәтә Камил абый. Икенче юлы яшь егеткә җитдирәк, зуррак рольне ышанып тапшыралар һәм ялгышмыйлар: Мирсәй Әмирнең “Наилә” комедиясендә төп рольне Зиннәтне зур осталык белән башкарып чыга ул. 1958 елда Таҗи Гыйззәтнең “Чаткылар” драмасы буенча куелган спектакльдә Рамай ролен башкаргач, Камил абыйга “Исәнме, Рамай!” дип, таныш түгел кешеләр дә еш дәшеп китә торган булган. Шушы тамашаны караган халык артисты Рәшидә Җиһаншина: “Спектакль профессиональ югарылыкта куелган. Талантлы режиссер Мөхәммәтҗанов әсәргә җан өреп кенә калмаган, анда талантлы яшьләрне дә туплаган. Яшь талант Камил Саттаров Рамай образын тулы канлы итеп күрсәтә алды”, - дип, спектакльгә дә, анда уйнаучыларга да югары бәя бирә. Аннары Камил абый Мирхәйдәр Фәйзинең Хәлиле (“Галиябану”), Гамир Насрыйның Илдары (“Туган авылым”) булып танылa. Аның үз әсәрләре дә сәхнәләштерелә. Авторның “Җуа җыены” комедиясе зур уңыш белән бара. Спектакльгә музыканы Заһид Хабибуллин яза, җырлы-биюле бу тамашада төп рольне Камил абый үзе башкара.

Татар классикасы репертуарда төп урынны алып тора. Әйтик, Кәрим Тинчуринның “Кандыр буе” спектакле. Әсәрдәге Акбердин гаять катлаулы, психологик образ. Аны бары тик Михаил Шолоховның Давыдовы (“Күтәрелгән чирәм”) белән генә чагыштырырга мөмкин. Камил Саттаров Акбердин аша әнә шундый биеклеккә ирешә.

Камил абый көчле рухлы, якты образлар уйнарга ярата. Г.Насрыйның “Туган авылым” пьесасында колхоз председателе Илдар, К.Тинчуринның “Кандыр буе” әсәрендә егерме биш меңче Акбердин шундыйларга керәләр. Алар һәртөрле батырлыкка әзерләр, үз артыннан башкаларны ияртә беләләр.

Үзешчәннәр өчен юлбашчы образы турында хыялланырга да мөмкин булмаган бер заманда Касыйм Мөхәммәтҗанов драматург Габдулла Баһаветдиновның “Соңгы каракош” әсәренә туктала. Бу спектакльдә Камил Саттаров Ленин образын иҗат итә. Моның өчен алдан зур әзерлек эшләре алып бара: Мәскәүдә, Мавзолейда була, Ленинның китапларын укый, кинопрокаттан Ленин турында нәфис һәм документаль фильмнар алдырып, аларны карап, юлбашчының йөрешен, сөйләшүен, хәрәкәтләрен өйрәнә. Ильич ролендә уйнау өчен ике ел хәзерләнә. Шулай итеп, Татарстанда да беренче тапкыр үзешчән театр сәхнәсендә Ленин образы иҗат ителә. Ә Камил абый шушы хезмәтләре өчен КПСС өлкә комитеты һәм Татарстан Министрлар Советының Мактау грамотасы белән бүләкләнә. Шулай итеп, ул республикада Ленинны уйнаган бишенче артист була. Менә алар: Габдулла Шамуков, Нәҗип Гайнуллин, Шәүкәт Биктимеров, Әнвәр Фәсхетдинов, Камил Саттаров.

Иҗатының икенче өлешендә Камил Саттаров актерлыкны режиссерлык хезмәте белән алып бара. 1967 елда ул Урицкий исемендәге мәдәният сараеның үзе уйнаган татар театры коллективына режиссер итеп чакырыла.

Аннан Ленинградта СССР профсоюзларының югары мәктәбенең театр бүлегенә режиссерлыкка укырга керә. Шушы өч еллык мәктәпне бетергәч, һөнәри осталыгы шактый арта төшә.

Режиссер буларак, иң беренче Г.Әпсәләмовның “Алтын йолдыз” романын сәхнәләштерә. Ю.Әминовның “Тамырлар” әсәре буенча эшләнгән спектакль белән РСФСР күләмендәге смотрда катнашып, ул җитәкләгән коллектив лауреат дипломына лаек була. 1969 елда Профсоюзларның өлкә советы тарафыннан үткәрелгән “Театр язы” смотрында беренче урынны алалар. Ә тагын бер елдан 1970 елда бу коллективка “Халык театры” дигән

мактаулы исеме бирелә. Камил абый исә ТАССР Верховный Советы Президиумының Почет грамотасы белән бүләкләнә.

Спектакльләрдә үзе дә актер буларак катнаша Камил абый. Ул шактый җитди, катлаулы әсәрләрне сәхнәләштерә. Н. Исәнбәтнең “Мәхәббәт турында җыр”, “Рәйхан”, М.Әмирнең “Тормыш җыры”, Ш.Хөсәеновның “Чулпан”, Ю.Әминовның “Тамырлар” әсәрләре һ.б. Режиссерның максаты – театр ярдәмендә ана телебезнең бөтен хиссиятен, нечкәлеген, миллилеген саклап калу, аларны яшь буынга җиткерү.

Тугандаш халыклар драматургиясен дә чит итми ул. Казах драматургы К.Шәмгытбаев һәм К.Байсәетовларның “Кияүләр” комедиясе күп еллар сәхнәдән төшми. Ч.Айтматовның “Талчыбыктай гүзәлем”, “Гүзәлем Әсәл”, Н.Анпиловның “Солдатның тол хатыны” әсәрләре дә Камил Саттаров куелышында тамашачыларның игътибарына лаек була. Ул куйган “Чулпан”, “Тамырлар”, “Тормыш җыры”, “Хатыннар” һ.б. спектакльләр Бөтенсоюз, Бөтенрусия, республика конкурсларында, фестивальләрендә лауреат була.

Татар профессиональ театрын төзүдә хезмәт иткән халкыбызның олуг шәхесе Касыйм ага Шамил белән озак еллар бергә эшли. Иҗат юлында аңардан күпкырлы һөнәри белем ала. Шулай ук үзешчән сәнгатьне үстерүдә эчкерсез булышлык күрсәткән режиссерлардан Ширияздан Сарымсаков, Пранзат Исәнбәт, Татарстанның атказанган артистлары Дилүс Ильясов, Гәүһәр Камаловага һәм башкаларга чиксез рәхмәтле ул.

Камил Саттаровның кырыктан артык зур күләмле, төрле милләт драматургларының пьесаларын сәхнәләштерүне һәм үзенең артист буларак 80нән артык образ иҗат итеп, меңнән артык спектакль һәм концертларда катнашып чыгыш ясавын искә төшерсәк, аның гомере моңлы бер җырга тиң икәнен белербез. Аның һәр роле, һәр спектакле профессиональ дәрәҗәдә. Театр аның өчен һөнәр түгел, ә гомерлек мавыгу, җан азыгы булып кала. Халык театрын бер сулыш, бер ритмда эшләтә алу өчен режиссерга педагог та, җитәкче дә, киңәшче дә була белергә кирәк. Нәкъ менә шушы сыйфатларның булуы Камил Саттаровка, аның коллективына уңышлар артыннан уңышлар алып килә дә инде.

К.Саттаров җитәкчелегендәге үзешчән коллективлар Казан, Чаллы, Мәскәү, Ульяновск, Куйбышев, Санкт-Петербург, Уфа, Пермь, Магнитогорск, Самара, Ташкент, Тольятти кебек шәһәрләрдә, Алмания, Маҗарстан, Болгария шикелле ерак илләрдә дә уңышлы чыгыш ясыйлар. Хәер, ул кайда гына булмасын, әйтик – Арчадамы, әллә Бохара белән Ташкенттамы – аңа рәхмәт сүзләрен ихлас күңелдән әйтәләр. Режиссер-актерның хезмәте югары бәяләнә, 1972, 1984 елларда талантлы иҗатчы СССР Мәдәният министрлыгы һәм мәдәният хезмәткәрләре профсоюзының үзәк комитеты тәкъдим иткән “Авылга шефлык мәдәни хезмәте күрсәтү өчен” дигән истәлек дипломы, Татарстан хөкүмәте һәм Президентның Мактау грамоталары белән берничә тапкыр бүләкләнә. Аңа “Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре” дигән мактаулы исем бирелә.

Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Камил Саттаров заманында Беренче Бөтенсоюз үзешчән сәнгать фестиваленең лауреаты була, алтын медаль белән бүләкләнә.

Үзенең дәвамчылары-шәкертләре белән дә горурлана Камил Саттаров. 500дән артык кеше аның театр мәктәбен узган. Шуларның 50дән артыгы Казан дәүләт мәдәният-сәнгать академиясен, 11е Казан театр училищесын тәмамлаган. Алар арасында Татарстанның һәм Русиянең халык артисты Алсу Гайнуллина, Татарстанның халык артистлары Миңгол Галиев, Лидия Әхмәтова, Әсхәт Хисмәтов, Минзәлә Татар драма театры артисты Хафиз Хамматуллин, филология фәннәре докторлары Фәрит Бәширов һәм Рамил Исламов та бар. Ике композиторны - Илфат Дәүләтшин һәм Инсаф Хәбибуллинны да “ачкан” кеше әле ул. Беренче тапкыр халык театрына йөри башлап, Петербург театр-музыка һәм кино институтын тәмамлаган Шамил Галиуллин, Сания Гыйльфанова, Гөлфия Фәйзрахманова, Фирдания Морадымова, Казан сәнгать һәм мәдәният академиясендә укыган Наил Сафиуллин, Наҗия Әхмәтова, Гөлчирә Камалиева, Казан театр училищесында белем алган Марат Баязитов, Әнвәр Шайхаттаров, Тәскирә Гатиятуллина, Фидания Сәләхова, Зөһрә Сибгатуллина кебек халык арасында абруй яулаган сәнгать әһелләрен дә горурлык белән телгә ала Камил Саттаров.

Камил абый тәрбияләгән режиссерлар – бүгенге көндә республика халык театрларының әйдәп баручы режиссерлары. Менә алар: Кукмарада “Идел-йорт”ның гран-при иясе Рамил Сәләхетдинов, Балтачта – Илдар Насыйбуллин, Арчада гран-при иясе Рафис Сәләхетдинов, Казанның Сәетгалиев мәдәният йортында – Рафис Фазылҗанов, Балык Бистәсендә – Рифкать Галиев, Мамадышта – Марат Баязитов, Бөгелмәдә – Флера Шәрипова, Чүпрәледә – Ринат Кәлимуллин.

Танылган режиссер озак еллар Татарстан Мәдәният министрлыгы фәнни-методика үзәгенең халык иҗаты бүлеген җитәкли, четерекле авыр заманда да республикабызда эшләп килгән халык театрларын саклауда хезмәт куя.

Кайчандыр үзе эшләгән Урицкий исемендәге мәдәният сараен да онытып бетерми Камил абый. Биредә ай саен диярлек республика шәһәр-районнары үзешчән сәнгать көчләре чыгыш ясый, халык театрлары спектакльләр белән килә. Ә программаларның авторы – мәңге картаймас, яшь күңелле, кайнар йөрәкле, җилдән җитез Камил абый Саттаров. Аны һәр төбәктә беләләр, хөрмәт итәләр.

2000 нче елда Республикадагы халык театрларын Казанга җыеп алып, фестиваль-конкурс оештыру идеясе туа. Бу фестиваль “Идел-йорт” халык театрлары фестивале дип атала. 2005 нче елдан аның җитәкчесе итеп Камил Саттаров билгеләнә. Беренче фестивальдә нибары алты гына халык театры катнашкан булса, тора-бара катнашучы коллективларның саны арта. Нәтиҗәдә, бу фестиваль төбәкара дәрәҗәсен ала. Фестивальнең әһәмияте бик зур: анда татар теле сәнгатьчә, образлы итеп тамашачыга җиткерелә. Галиәсгар Камал, Нәкый Исәнбәт, Мирхәйдәр Фәйзи, Кәрим Тинчурин исемнәрен халык күңелендә беркетү чарасы буларак та “Идел-йорт” зур әһәмияткә ия.

Классик язучылар әсәрләренең балкып сүнмичә яшәүләрендә, халык театрларының үсешендә, балаларның театр сәнгате белән кызыксынуларында Камил абыйның хезмәте бик зур. “Идел-йорт” фестивале масштабының зур булуы, үзешчән артистларның осталыгын чарлау – шулай ук Камил әфәндәнең тынгысыз хезмәте нәтиҗәсе. Камил ага салган сукмак юлга әйләнде, ул юл башкаларны да үзенә чакырып тора.

Камил абыйдан тормыш девизыгыз нинди дип сораганда, ул: “Мин гомер буе беренче һәм бердәнбер булырга омтылдым”,- дип җавап бирде. Максатына ирешкән, язучы Аяз Гыйләҗев, драматург Хәй Вахитның “халык театрының профессоры”, “халык театрының атасы” дип биргән бәяләмәләре дә моны раслап тора.

Мәдәният тавына менгәндә яулаган үрләрен искә алсак, режиссер, Россия Федерациясенең атказанган хезмәткәре Камил Саттаров “Хезмәт ветераны”, “СССРның мәдәният отличнигы”, “Казанның 1000 еллыгы медале”, башка бик күп шәрәфле бүләкләргә һәм исемнәргә ия. Әмма иң зур исеме аның – Чын кеше. Менә инде сиксән елдан артык Камил абый бу исемгә тугрылыклы калып, үзедәй күпме кешелекле талантларны тәрбияләп үстерде.

Бу инде таудай эш башкарган гына түгел, таулардан да зур хезмәт керткән танылган якташыбыз, сөекле ветеранибыз, егетләр солтаны! Димәк, үз илеңдә солтан булу - мөмкин эш икән бит!

1998 нче елдан башлап, Камил абый һәр елны туган авылы Югары Сәрдәгә кайта. Авылдашлары белән очрашу оештырып, Татарстан районнарының (Кукмара, Арча, Әтнә, Биектау, Теләче, Мамадыш, Питрәч, Балтач һ.б.) сәнгать коллективлары белән безне таныштырып, авыл халкына зур бәйрәм ясап китә. Үзенең шәхси архивында булган китаплар, сувенирлар, язмаларны алып кайтып, мәктәпкә, авыл клубына, китапханәгә, мәчеткә бүләкләр ясап тора. Без барысы өчен дә Камил абыйга рәхмәтле. Аның иҗатын, тормышын мәңгеләштерү йөзеннән, укытучы апаларыбыз материалларны мәктәп бинасындагы бер бүлмәгә урнаштыра башладылар. 2017 нче елда аның иҗатына багышланган күргәзмә әзер булды. Аны оештыручы укытучылар Гөлнур апа Хөснетдинова, Гүзәл апа Закирова, китапханәче Рәйхана апа Сабирова, клуб мөдире Ләйлә апа Җиһангировалар әлеге эштә күп көч куйдылар. Хакимият тарафыннан бина диварына “Бу мәктәптә 1944-1945 елларда Россиянең театр әһелләре берлеге әгъзасы, Татарстанның

атказанган мәдәният хезмәткәре, танылган режиссер, артист Камил Саттаров укыды” дигән мәрмәр такта куелды. Күргәзмәдә күп урынны спектакль афишалары, фотолар, китаплар, истәлекле бүләкләр алып тора.

Һәм, ниһаять, 2017 елның 8 октябре көнне минем туган авылым - Әтнә районы Югары Сәрдә авылында тарихи вакыйга булды. “Халык театрларының” атасы дип хөрмәт ителүче, республикабыз театр әһелләренә һәм, гомумән, театр сөючеләргә яхшы таныш булган Камил Саттаровның үзе укыган мәктәбендә, ягъни минем мәктәбемдә даими эшли торган иҗат күргәзмәсе ачылды.

Күргәзмә ачылышына Камил аганың кызы Резедә Хөрмәтуллина да кайтты. Аның да сәнгатькә тартылуына, консерваториядә белем алуына әтисе зур йогынты ясаган икән. “Әтием кечкенәдән җитәкләп театрга йөртте. Камал театрының бер премьерасын да калдырмадык. Әле алай гына да түгел, үзе куйган спектакльләрдә үземә дә массовкаларда катнашырга, кечкенә кыз ролендә сәхнәгә чыгарга туры килә иде. Шуңа күрә сәхнәгә чыгарга кыенсынмыйм, үземне иркен, табигый тотам” дип хатирәләр яңартты Резедә апа Камилевна. 4 яше тулуга ук кызы Резедәне музыка түгәрәгенә йөрткән. Аны 6 яшеннән консерватория каршындагы махсус музыка мәктәбенә укырга алганнар. Хәзер Резедә Хөрмәтуллина – танылган музыкант, Федераль университетның доценты, педагогика фәннәре кандидаты, халыкара конкурслар лауреаты. Камил абыйның оныгы Диана да әнисе укыган мәктәптә белем ала. Ул да инде күпләгән бәйгеләрдә катнашып, җиңү яуларга өлгергән.

Әлеге чарада Татарстан Республикасы мәдәният министрлыгыннан Татарстанның һәм Россиянең атказанган мәдәният хезмәткәре Луиза Гәрәева да катнашты.

Бу чара “Ватаным Татарстан” газетасында яктыртылды, ТНВ каналының “Манзара” тапшыруында берничә сюжет күрсәтелде. Шулай итеп, Камил абый безнең Югары Сәрдә авылын Татарстан Республикасына гына танытып калмады. Ни өчен дигәндә, хәтта чит өлкәләрдән дә безнең якташларыбыз тарафыннан шалтыратулар, котлау хатлары җибәрүчеләр булды. Бүгенге көндә авылга кайткан кунаклар, иң беренче итеп, Камил абый күргәзмәсе белән танышалар.

Иҗат гомерне озайта, дәрткә дәрман бирә. Без бу олы шәхескә сәламәтлек, озын гомер телибез!

Эзләнү эшеннән соң мин шундый нәтиҗә ясадым: Камил Саттаров – халык театрлары режиссеры һәм артисты. Классик язучылар әсәрләренең балкып сүнмичә яшәүләрендә, халык театрларының үсешендә, балаларның театр сәнгате белән кызыксынуларында аның хезмәте бик зур. “Идел-йорт” фестивале масштабының зур булуы, үзешчән артистларның осталыгын чарлау – шулай ук Камил Саттаровның тынгысыз хезмәте нәтиҗәсе. Мәдәният өлкәсендә зур тырышлык куючы, аны киң мәйданга чыгаруда зур хезмәт күрсәтүчеләр арасыннан ул иң күренеклесе.

***Кулланылган әдәбият исемлеге***

1. “Ватаным Татарстан”, “Шәһри Казан”, “Мәдәни җомга”, “Татар иле”, “Татарстан яшьләре”, “Әтнә таңы” газеталарында, “Идел”, “Сәхнә” журналларында чыккан басма материаллар.

2. Иҗат күргәзмәсе материаллары

3. Интернет-ресурслар.

# СУГЫШНЫҢ ТЕРЕ ШАҺИТЛӘРЕ

*Хаммадиев Сает Саматович, ученик 6 класса*
*Научный руководитель – Мухаметшин Руслан Рашитович ,*
*”МБОУ «СОШ с.Олуяз” Кукморского муниципального района РТ»*

Фәнни-тикшеренү эшемнең темасы «Сугышның тере шаһитләре» дип атала. Бу теманы сайлавым очраклы гына түгел, чөнки мәктәбебездә хәрби-патриотик юнәлештә бик күп төрле эшләр алып барыла. Шуларның берсе-солдат хатларын җыю, өйрәнү. Минем үз кулларыма солдат хатларын тотып карагач, алардагы кешеләрнең язмышлары белән танышкач бу турыда күбрәк беләсем килде.

2018 нче елда Бөек Җиңүнең 73 еллыгын каршы алырга җыенабыз.Әлеге фәнни-тикшеренү эше солдат хатларын һәм аларның бүгенге көндә әһәмиятен ачуга багышлана.

Фәнни-тикшеренү эшем 2 өлештән тора : эзләнү һәм теоретик өлешләрдән. Теоретик өлештә хатларның килеп чыгышы һәм эволюциясе фронттан килгән хатларның сакланышы, аларның төрләре өйрәнелсә, тикшеренү өлешендә исә фронтовик-авылдашларыбызның сугыштан язган хатлары турында сүз бара. Шулай ук бу өлештә классташларым арасында «Бабайларыбыз сугышта» дип исемләнгән анкета нәтиҗәләре дә күрсәтелә.

Максат: хатларның үсеш тарихын ачыклау; солдат хатлары турында информация туплау, аларны саклау; сугыш афәтенең һәр кеше, һәр гаилә өчен фаҗига булуын ачыклау;

Максатка ирешү өчен куелган бурычлар:

-тарихи чыганак буларак хатларның килеп чыгышы, аларның формалары белән танышу;

-солдат хатларының информацион мөмкинлекләрен ачыклау;

-сугыштагы тормышның хатларда чагылышын билгеләү;

-тынычлыкның кадерен белергә өйрәтү.

Көтелгән нәтиҗәләр:

-сугыш чоры турында фронттан язылган документаль белешмәләр;

-тарихны саклау һәм аны киләчәк буыннарга тапшыру;

Эзләнү эшенең объекты:

-солдат хатларының килеп чыгышы:

-авылдашларыбызның сугыштан язган хатларының төп нөсхәләре.

Тикшеренү алымнары:

-хатлар турында информация туплау һәм аларны анализлау;

-солдат хатларын өйрәнү;

-классташлар арасында уздырылган анкета нәтиҗәләре;

-өстәмә әдәбият, музей материаллары белән эшләү.

Тикшеренү эшенең төп чыганаклары:

Бу фәнни эшемне башкарганда мин авылдашларыбызның яу кырыннан килгән өчпочмаклы солдат хатларын өйрәндем, классташларым арасында уздырылган анкетага нәтиҗәләр ясадым, татар шагыйрьләренең сугыш турында язылган шигырьләрен файдаландым, ә төп материалны исә мәктәбебезнең туган якны өйрәнү музееннан алдым.

*Төп өлеш.*

Без бүген кечкенә кәгазь битләренә язылган сугыш хатирәләрен искә алырбыз.Хатлар.Хатлар...Өчпочмаклы,ак,зәңгәр яки ал конверлы,читенә кыр почтасының тәртип саны куелган.Әллә ничә төрле кулъязма,төрле төстәге карандашлар,төрле телдә язылган.Бу хатларда бер генә теләк:”Җиңүгә ышаныч!”

Солдат хатлары.Күз алдыгызга китерегез:кыска гына ял вакытында солдат окопта яки блиндажда ,кәгазен калай савыт төбенә яки тез башына куеп, хат яза. Дошманга булган ачы нәфрәте дә, сугыш авырлыгы, яраларының сызлавы, иптәшләренең һәлак булу кайгысы-барысы да шушы хатка сыеп беткән. Бу кечкенә генә кәгазьдә дошманны чигендереп алган шәһәрләр һәм авыллар турында да сөйләнә.

Солдат язылып беткән хатын бик пөхтәләп, өчпочмаклап төрә, адресын яза һәм кыр почтасына илтеп сала. Шулай ул, иң изге теләкләрен әйтеп, гаиләсенә сәлам хаты җибәрә.Солдатлар ут эчендә. Кайберләре, искиткеч батырлык күрсәтеп, сугыштан исән чыга, ә кайберләре, дошман белән соңгы сулышына кадәр көрәшә. Ә хат, канатлы кош кебек, еракеракка "оча". Ул фронтчының ялкынлы сүзләрен туган иленә, гаиләсенә, якын кешесенә житкерә.

Фронтовикларның шәхси хатлары бүгенге көндә зур кызыксыну уяталар. Алар сугыш ветераннарының психологиясен өйрәнүдә төп чыганак һәм хат язу культурасын ачыклауның төп факторлары булып торалар.

Фронттан килгән хатлар белән хәзерге хатлар арасындагы аерымлык нидә соң? Нәрсә соң ул хат? Хат (хәбәр) ул кәгазьгә яки башка материалга төгәл һәм ачык итеп язылган текст. Аның төп вазыйфасы- ике яки берничә адресат арасындагы язма хәбәр.

Хатның үсеш тарихына күз салыйк әле. Элек кәгазьгә яки бүтән материалга кулдан язылган хәбәрне хат дип атаганнар. Хатлар чүлмәк ватыкларына, пергаментка, каен тузына һ.б. материалларга язылган.

Хәзерге вакытта хат дип электрон формада җибәрелүче хәбәрләрне дә атыйлар.Моның өчен электрон почталар , кәрәзле телефоннар аркылы SMS хәбәрләр җибәрүләр киң таралды, хәтта инде аудио-видео материалларны да шулай җибәрәбез бер-беребезгә.

Дары исе, махорка исе сеңгән солдат хатларына әйләнеп кайтыйк әле. Сугыш тынып торган арада берникадәр мизгелгә генә туган якка очып кайтырдай булып, тыныч көннәрне сагынып язылган хатлар алар. Ләкин аларның барчасы да адресатка барып ирешә алмаганнар, чөнки солдатларның күбесе якыннарыннан хатларны үз исемнәренә түгел, ә бәлки хәрби часть адресына юлларга кушып язганнар.Советлар Союзының Халык Комиссариатының №25 карары нигезендә сугыштан хатлар түләүсез җибәрелгәннәр һәм ул "кыр почтасы" дип аталган.

Солдат хатларының төрләре. Өчпочмаклы, дошманны җиңүгә өндәгән плакат формасындасындагы почта карточкалары, фронт тормышына багышланган рәсемнәрдән торган солдат конвертлары....Ләкин алар арасында иң киң кулланылышта булганыөчпочмаклы хатлар. Ул гади кәгазьдән башта уңга , аннан сулга бөгеп, калган өлешен өчпочмакның эченә яшерү юлы белән ясалган . Хатны сыламаганнар, чөнки фронттан тылга китүче һәрбер хатны хәрби цензура укыган, тикшергән, марка шулай ук кирәк булмаган, адрес өчпочмакның тышкы өлешенә язылган. Өчпочмаклы хатлар гадәттә солдатлар тарафыннан язылган, а хәрби исемнәре булганнар хатларны конвертларга салып җибәрә торган булганнар.

Яу кырыннан кайтмаган солдат хатларын укыганыгыз бармы? Кайтмый калганнарның гади генә сүзләрендә – "тиздән кайтырбыз", "мин кайткач, демонстрациягә чыгарбыз", "киләсе бәйрәмдә бергә булырбыз" дигән сүзләрендә дә үзенә бер сагыш бар кебек.

Инде 72 ел узган... Әйдәгез, бергәләп укыйк шул хатларны.

Безнең алдыбызда авыр сугыш елларында, ут эчендә, окопларда һәм блиндажларда язылган солдат хатлары. Алар солдатның йөрәк түреннән чыккан хисләрен, уй кичерешләрен ачык чагылдыралар. Хатлар инде вакытлар узу белән саргайганнар, еллар тузаны да кунган, кайберләренең сүзләрен дә танырлык түгел.

Хатлар, хатлар... Архивларда, сандыкларда, китап араларында һәм төргәкләрдә сакланган бу хәзинәләр бик күп нәрсә турында сөйлиләр. Алар каһәр сугышка, аны башлаучы немец фашистларына ләгънәт укыйлар, алар киләчәк сугышларның булмавын телиләр. Бу хатлар тирән эчтәлекле, тирән фикерле, ялкынлы сүзле, алар кайгылы да, шатлыклы да. Кайбер хатларны укыганда күздән яшь атылып чыга, ә кайбер хатлар көч һәм дәрт өсти, рухны күтәрә, җиңүгә ашкындыра. Ничә төрле фикер, кичереш! Хатларда дулкынгандыргыч җөмләләр күп. Чөнки аларда йөзләрчә, меңнәрчә сугышларның йөрәк ялкыны бар. Бу хатлар, авыр сугыш чорын чагылдырган кыйммәтле документлар булып торалар...

Сугыш корбансыз булмый. Көрәштә җиңү яулаганда, ут белән юл ярып алга атлаганда снаряд яки пуля тиеп, бик күпләр соңгы сулышларын алдылар. Коралдаш дусларны Европаның төрле җирләрендә күмеп калдыру-солдат өчен иң авыр, тетрәткеч хәл. Солдат йөрәге таш түгел, аның җаны сыкраган, кайгы хәсрәт кичергән минутлары да була...

**Хат бар икән, димәк, исән.**

Өчпочмаклы солдат хатлары. Кош теледәй бу хатларны һәр өйдә түземсезлек белән көтеп алганнар. Хаты килсә, исән икәнен белгәннәр. Бәлки шуңа да әбекәйләребез аларны гомер буе кадерләп, сандык төбендә саклагандыр. Солдат хатларында аларның күңел җылысы хәзер дә саклана кебек.

Күпме өмет, сөю, сагыну хисе
Өчпочмаклы солдат хатында
Кат-кат укый-укый һәрбер сүзе,
Һәр җөмләсе аның ятланды.
Әнкәем, хат язам!
Ничек соң хәлләрең?
Юрама яманга,
Килмәсә хәбәрем.
Әткәем, хат язам:
Юк башым игәнем,
Һәрвакыт хәтердә
“Сынатма!” дигәнең

**Сугыштан килгән хатлар**

**Хәмәтдинов Хәлиулла**

1924 нче елда Олыяз авылында туа. Башлангыч белемне дә шунда ук ала. Ә 5-7нче сыйныфларны Зур Сәрдек мәктәбендә укый. Кара чәчле, кара күзле, гәүдәгә калкурак, ак чырайлы чибәр кеше булган. Колхозда бригадир булып эшләгән. Сугышка 1942 нче елның гыйнвар аенда китә. Хатлары килеп торган. “Емеки урманыннан 450 км. Үзебезгә таба кайттык. Хәзер тайгада урман кисәбез, эш авыр”,- дигән юллар бар. Хәбәрсез югала.

***Хәмәтдинов Хәлиулла хаты***

*1 нче хат.*

*Сагынычлы сәлам хатымны язам туган илләремдә яшәп калучы Галимә әнием, Шәрифулла энем, Нәсимә, Хамия сеңлемә. Урал таулары кадәр сәламемне җибәреп калам. Дәү әнигә, барча агай энеләргә, күрше-күләннәргә, мине сораганнарга сагынычлы сәлам. Сәлам соңында үзебезнең хәлләр хәзергә таза-сау гына яшибез, хезмәт итеп ятабыз. Ешке урманыннан 450 км үзебезгә таба кайттык. Хәзер тайгада урман кисәбез, эш бик авыр, сезнең 20 майда язган хатыгызны алдым. Әни, минем өчен кайгырма, тору, ашау әйбәт. Авылда яшь бәрәңге җитешкәндер инде, кәҗә бәкәйләре, каз бибиләре урамдамы, үсәләрме?*

*2 нче хат.*

*Әкрен генә хезмәт итеп ятабыз. 21.03–23.03 язган хатларыгызны алдым. Аллага шөкер, исән икәнсез, кәҗә дә тора икән, буаз икән, Шәрифулла урманнан туктаган икән, мин киткәннән бирле ашарга бирмәгәч, ашарыгызга беткәндер дип бик кайгырдым. Әни, минем тору, яшәү ярый әле. Ашарга җитә, өс бөтен, ну сезнең өчен генә бик кайгырам. Нәсимә дә авыргач, үзеңә йөрергә бик күптер. Нәсимә исән-сау терелсен дип телим. Әни, бәрәңге дә исән-сау чыккач әкрен генә торырлык әле дип күңелемне юатам. Үзебез әле хәзергә учебныйда өйрәнәбез, 1 майда отправка диләр. Өчебезне аермасалар ярар иде дип кайгырабыз. Занятие каты. Авылны бер дә онытып булмый. Шәрифулла энем, әнинең сүзен тыңла, әнигә каршы эндәшмә, бригадир эшкә кушса, тыңла, киреләнмә.*

*Без 3 нче батальон, Гафур 2 нче батальонда иде, ул аннан күчте.*

*17.03.1943 ел. Әни минем өчен кайгырма, елама. Без бер илдән чыгып киткән инде. Исән йөрсәк, бер кайтырбыз әле, Алла боерса. Бу хатны алгач, бөтен авыл хәлләрен әйтеп хат язарсыз.*

*Читинская область, ст. Сибаки н/я к19.*

**Мөхетдинов Хөснетдин**

1900 нче елда Олыяз авылында туа. 1919 нчы елда гражданнар сугышында катнаша. Аннан кулы яраланып кайта. 1941 нче елның 24 нче августында сугышка китәргә повестка ала, 26сы көнне чыгып китә. 7 бала, төпчеге әле тумаган, бер ана тәрбиясендә калалар. Хөснетдин абый өйдән чыгып киткәндә башын стенага терәп бик елаган, чөнки ул сугышның нәрсә икәнен белә. Аның сугыштан өч-дүрт хаты килә. 1947 нче елның 10 июнендә Кукмара хәрби комитетына "Хәбәрсез югалган" дигән извещение килә.

***Мөхетдинов Хөснетдин хаты***

*Бисмилләһир-рахманир-рахим.*

*Сезгә сагынычлы кайнар сәламнәр җибәреп хат язучы Хөснетдин дип белерсез. Өйдә калган газиз хәләлем Сәхибҗамалга һәм дә улым Вәкыйф, кызым Әминәгә, улым Нәкыйпкә, кызым Нәзирәгә, Наҗия кызыма, Файзылхак улыма һәм Мәүлидә кызыма сагынычлы кайнар сәлам язам, хәер догада калам.*

*Безнең хәлләрне сорасагыз, без хәзер Казаннан чыгып киттек, юлда барабыз, хәерле булсын сездә минем балаларым да йөрәгемне ярып аласыз, икмәкләрне колхоздан Мәлик сорасын. Үзебез Олыяздан 8 кеше: Шәрип, Фәйзи, Гаффар, Миңнегали, Мәүлид һәм башкалар. Күрше авыллардан бар. Кукмарадан һәм Казаннан да бар. Өйдә ничек булса да бер-берегезгә булышып, дөньяны алып барыгыз. Исән-сау кайтсам онытмас идем. Алла хәерле кылсын, Алладан ни язган, окопта ятабыз 6 сентябрьдә, беребезгә дә берни булмады. Барыбыз да исән булырга кирәк, бер батольонда бер ротада Гаффар, Шәриф үзе бер ротада. Окопта яткач, аста балчык, өстә балчык, ябынырга әйбер юк, менә шулай торабыз.*

*Безнең хәлләр ярый, без бүген Мәскәүдә, бүген 3 нче көнне моннан кайда булса да тагын күчерәләр, кайда икәнен һич белгән юк әле. Ленинград янына дип әйтәләр, менә ашап чыктык, 13 август бүген атарга өйрәтәләр. Авыллардан барыбыз 8 кеше без. Сезне дә бик сагынам, уйлыйм.*

*Ашарларыгызга бармы, минем өчен кайгырмагыз, сез анда 8 җан нәрсәләр киясез? Ягарга утыннарыгыз бармы? Исән-сау торыгыз. Күрешергә язган булса, күрешербез.*

***Гәлләмов Галим хаты***

*Сагыну хаты.*

*Сезки үзебезнең анда яшәүче дөньяда якын күргән иптәшем Хәнифәгә, Хәмидә, Рузилә һәм Хәтимә кызыма, әнигә һәм барча туганнарга бик сагынычлы бик күп булган сәламнәремне җибәреп калам. Әби, бабай, Шакир абзыйларга, Мортазаларга бик күп сәлам. Сәлам соңында үзем исән-сау, ул тарафтан сезне дә сәламәттер дип калам. Ну, карчык, ни хәлләрегез бар? Исән торасызмы? Күптәннән хат алганым юк. Ну, безнең хатлар бик озак йөрер сезгә, чөнки иптәшләр күп кенә киттеләр, без дә китәргә хәзерләнгән идек, китәргә дип строить иткәч, 8 кешене калдырдылар. Тагы шушы 10–15 көн эчендә ни булса да була инде. Аллага шөкер, әлегә үзем исән-сау. Карточка җибәрәм, бик әйбәт булмаса да карарсыз. Хатыңны алдым, моңа кадәр бик әйбәт торган идек. Моннан соң авылга барсак кына туры китереп бу хатны салырмын. Үзең хат язганда төшләреңне әйтеп яз, синең төшләр дөрес була торган иде. Ярый, таза-сау булыгыз, күрешәчәк булса, бер кайтырбыз әле. Карчык, бик сагынам сезне. Хат языгыз. 8.02.1943 ел.*

Солдат хатларын өйрәнү һәм алар турында информация туплау максатыннан мин классташларым арасында сораштыру уздырдым. Алар түбәндәге сорауларга җавап бирделәр:

1. Аңлатмаларның мәгънәсен аңлатырга:

А) фронттан килгән хатлар;

Б) өчпочмак

В) похоронка (кайгылы хәбәр)

2. Бөек Ватан сугышында катнашкан туганнарыгыз бармы?Булса кем һәм кая хезмәт иткән?

3. Алардан килгән хатлар сакланганмы?

Сорашу алып бару нәтиҗәсендә мин шуны ачыкладым: күпчелек сыйныфташларым солдат хатларының ни икәнен беләләр, шуның белән беррәттә сугышта катнашкан әби-бабаларының исемнәрен язганнар. Әмма аларның кайда хемәт иткәннәрен һәм хәрби дәрәҗәләрен язучылар юк.

*Нәтиҗә.*

Без укыдык аны ятимлектән
Җаннар өзгәләнгән чакларда
Без укыдык аны “әткәй”, диеп,
Бер дәшәсе килгән чакларда.
Әткәй кайткан кебек була иде,
Кулга алсаң шушы хатларны.
Җиңү көнен якынайтышты алар
Җиңү килде. Әткәй кайтмады

Җиңү һәм көрәш юлы озын булды, авыр булды. Тарихи сугышта катнашкан батыр якташларыбызның хатлары алдагы буынга сугышның дәһшәтле сулышын җиткерер, бу онытылмас елларда сугышчыларның күңелен биләгән югары һәм изге хисләрне ачып салыр, мондый сугышларны һич тә булдырмаска, дөньяда тынычлыкны нык сакларга дигән васыятьләрен җиткерер.

Хатларның кайсын гына алсак та җиңүгә ышаныч, аларга шушы авыр елларда көч биргән һәм ышаныч өстәгән. Гаиләләренә язган хатларында да авырлыкларга карамастан җылы сүзләр табып җиңүнең киләсенә ышандырганнар. Хатларның кайсын гына кулга алып укый башласаң да күзләргә ирексездән яшь килә. Бүгенге көнебез өчен үзләренең гомерләрен аямыйча башларын салган совет солдатларының батырлыгы безнең йөрәкләрдә сакланыр. Безнең мәктәптә эшләп килүче «Хәтер» төркеме укучылар белән еш кына солдат хатлары белән әңгәмәләр уздыра, , тыныч тормышның кадерен белергә өйрәтә, яшьләрне актив булырга, туган ил өчен бөтен көчне, хәтта гомерне дә кызганмаска кирәклеген каһарманнар мисалында раслый.

Шушы авыр елларда да чын солдат булып намусын югалтмыйча , батырларча илебезне саклаган, безнең киләчәгебез өчен үзләренең гомерләрен аямыйча хәлак булган ир - егетләребезнең һәм кызларыбызның батырлыгын халыкка җиткерү һәм бу еллар беркайчанда кабатланмасын дигән теләктә калабыз. Солдат хатлары-сугыш елъязмасы алар, аларны барлыйк, аларны үзебезнең хәтерләрдә саклыйк.

*Кулланылган әдәбият:*

1.Мәктәпнең туган якны өйрәнү музееннан алынган материаллар.
2. Авылыбыз тарихы «Татарстаннын Кукмара төбәге Олыяз авылы тарихы»
3.Интернет- ресурслар:
1.nsportal.ru/nachalnaya-shkola
2. http://www.klassnye-chasy.ru/klassnyy-chas-velikaya-otechestvennaya-voyna

# МУЗЕЙ В ЧЕМОДАНЕ

*Хасанова Диля Маратовна, ученица 10 класса*
*Научный руководитель – Хасанова Гузалия Гаптельнуровна*
*МБОУ КСШ № 3 Кукморского муниципального района РТ*

*Цель проекта*: Формирование интереса к истории родного края средствами музейной педагогики.

Задачи:

1.Приобщение к культурным и историческим традициям родного края.
2.Развитие чувства духовности и патриотизма у подрастающего поколения.
3.Воспитание музейной культуры.
4.Выработка навыков общения с музейными предметами.
5. Предоставление подлинных материалов из фондов музеев.

Период и этапы реализации:

| Этапы | Деятельность | Сроки |
|---|---|---|
| I этап | Сбор информации, подготовка бесед с учениками. | сентябрь-октябрь 2016 г. |
| II этап | Сбор экспо натов | ноябрь-декабрь 2016 г. |
| III этап | Проведение бесед, внеклассных мероприятий, школьных мероприятий, художественно-литературных вечеров, экскурсий, тематических линеек | январь-май 2017 г. |

Обоснование проекта. В нашем музее много материала и экспонатов, рассказать о каждом из них за одну обзорную экскурсию невозможно. Необходимы тематические лекции, а также новые формы проведения лекций и экскурсий. Какую новую форму работы мы можем выбрать для детей детского сада? Форму игры, так как дети этого возраста познают мир в процессе игры. Для детей более старшего возраста нужны иные формы работы. Тогда мы обратились за помощью к мультимедийным презентациям, так как с помощью презентаций можно грамотно, интересно и содержательно провести полноценную, развернутую лекцию в любой аудитории. Также мы решили наглядно представить экспонаты из фондов музея и рассказать о них аудитории в форме мобильного «Музея в чемодане».

Таким образом, актуальность нашего проекта заключается в популяризации историко-культурного наследия поколений, прививании подрастающему поколению уважения к истории своего края.

Содержание проекта:

Дети имеют возможность приобщиться к культурным и историческим традициям родного края, соприкоснуться с прошлым через живое восприятие, через реальный предмет – музейный экспонат, стать непосредственным участником действия.

Участники проекта:

Учащиеся школы, школы, воспитанники детских садов.

Сроки реализации проекта: В течение года.

Механизмы реализации проекта.

Представленная проектная работа реализуется в следующих формах:

- ✓ сбор и анализ информации;
- ✓ презентации, встречи, беседы;
- ✓ участие в военно-патриотических конкурсах;
- ✓ ведение научно-исследовательской работы;

В рамках проекта применяются следующие средства:

- ✓ использование ресурсов сети Интернет;
- ✓ походы в районные библиотеку, музей;
- ✓ цифровые средства (проектор, ПК);
- ✓ информационное пространство школьного сообщества в социальной сети.

Программа реализуется руководителем проекта, учащимися школы с помощью музейных экспонатов, фотодокументов, слайдов, фильмов, творческих заданий.

Методы, использованные в работе над проектом: исследовательский, информационный.

Ожидаемые результаты:

Мы надеемся, что, благодаря проекту «Музей в чемодане», у учеников класса, школы сформируется интерес к истории родного края, сформируется идентичность «Я – гражданин Татарстана», «Я – гражданин России», дети научатся обращаться с музейными экспонатами.

*Где-то в дальнем углу антресолей*
*Дерматиновый, пылью покрытый,*
*Чемоданчик потертый, забытый.*
*В нем хранятся обрывки историй.*

В последнее время, совершенствуя работу с экспонатами и экскурсантами, музеи активно используют разнообразные инновационные технологии, привлекая к участию посетителей (театрализации, интеллектуальные и ролевые игры, погружения в историческую атмосферу, интегрированные уроки, музейные праздники и т.д.) В своей деятельности они отходят от стереотипа – музея с застеклёнными экспозициями и табличками «Руками не трогать». Всё чаще экспонаты извлекаются из витрин и включаются в сферу общения всех тех, кто посещает музей.

Одной из интерактивных форм работы с музейными предметами, документами и материалами является так называемая идея создания «музея в чемодане», которая сегодня стала активно внедряться в практику. Экспозиция умещается в одном или нескольких чемоданах с музейными экспонатами, а также рисунками, текстами, фотодокументами, слайдами, фильмами, творческими заданиями. Отобранные вещи и материалы должны легко помещаться в чемодан.

Идея заключается в умении быстро развернуть мобильную выставку, в которой можно манипулировать музейными предметами, что очень важно для детей, поскольку они осваивают мир активно и практически.

Рассматривая эту новую форму музейной работы, следует отметить, что «Музей в чемодане» может применяться в двух вариантах: «Музей в чемодане» из музея (когда предметы какого-либо музея вывозятся за его пределы); «Музей в чемодане» для музея (когда редкие предметы собираются в чемоданы для конкретного музея, организации выставок с последующим возвратом их владельцам).

«Музей в чемодане», как переносной или передвижной, благодаря своей мобильности активно используется для организации выездных выставок, ведения занятий в отдалённых районах, разных городах, образовательных учреждениях и доступен самым широким слоям населения. Эта форма музейной работы позволяет решить целый ряд научно-исследовательских, образовательно-воспитательных и социально значимых задач, стоящих перед современными музеями.

Мы предлагаем познакомиться с проектом «Музей в чемодане», в основе которого лежит развитие познавательных навыков учащихся, критического и творческого мышления, изучение культурного наследия, взаимодействие учащегося с материальными предметами школьного музея и т.д. Этот проект помогает решить многие проблемы школьных музеев.

Проект предназначен для проведения выездных экскурсий для тех, кто не может прийти к нам. В ходе экскурсии мы ознакомим Вас с материальной культурой и бытом времён Великой Отечественной войны, и с ветеранами ВОВ. Все вещи из чемодана можно брать в руки, рассматривать, изучать. Для создания переносной экскурсии был взят старый

чемодан, в который положили подлинные экспонаты из экспозиции музея, рассказывающие о материальной культуре и быте времён Великой Отечественной войны.

Учащиеся ведут работу по нескольким направлениям. Одним из важных направлений является сбор материалов о ветеранах ВОВ и ветеранов тыла. Свою главную задачу мы видели в том, чтобы собрать как можно больше материала о живых ветеранах войны, а также их бесценные воспоминания и свидетельства, чтобы они стали достоянием истории и не были утрачены для потомков. Их большое воспитательное и историческое значение мы осознали тогда, когда эти ветераны стали постепенно уходить из жизни.

Во время Второй мировой войны на Земле погибло тринадцать миллионов детей! Война стала общей биографией целого поколения военных детей. Даже если они находились в тылу, всё равно это были военные дети. Их рассказы тоже длиною в целую войну.

Был собран огромный материал о ветеранах тыла. Ребята систематизировали этот материал и написали исследовательскую работу. Из воспоминаний Анны Петровны Гераклиной:

“Я жительница Кукмора. В 1941 году я училась в 7 классе. Папа ушел на фронт. Нас было пятеро детей. Мама работала на заводе и получала 175 рублей зарплаты. А тогда килограмм хлеба стоил в Казани 360 рублей. Мы голодали, целый день работали, помогали маме. Трудно было всем...”

Война принесла нам много слез, бед и огорчений. Наше поколения уже и не знает что это за горе и ужас. Но никогда нельзя забывать о наших предках, которые подарили нам свободу и голубое, чистое небо над нашей головой. Всегда их нужно помнить и почитать, ведь благодаря нашим ветеранам мы есть, мы живем. Мы помним наших ветеранов. В музее есть стенд, посвященный Героям Советского Союза, уроженцам Кукморского района: Ахтямову Сабиру Ахтямовичу, Воробьеву Петру Егоровичу, Загидуллину Фахрутдину Гильмутдиновичу, Газизуллину Ибрагиму Галимовичу, Савину Николаю Семеновичу, также ветеранам Таишевского микрорайона.

В музее есть фотография, в котором учащиеся в 1973 году встретились с Героем Советского Союза Воробьевым Егором Петровичем. В нашем микрорайоне одна из улиц называется его именем. Манзараская средняя школа носит имя Героя Советского Союза Ахтямова Сабира Ахтямовича.

Ветераны Великой Отечественной войны

Кузьмина Анастасия Михайловна родилась в 1923 году в деревне Чаксы Таканышского района.

Ей было 16 лет, когда началась война, До 1943 года она работала в тылу, в 1943 году её призвали на фронт, где она, пройдя ускоренное обучение, стала радиотелеграфисткой и была направлена в 44 стрелковый полк НКВД в Подмосковье в Очаково. В ее задачи входило своевременное оповещение войск об обстановке, о действиях противника, а также передача важной и ценной информации от Главного командования на фронты. Не раз ей приходилось выходить на линию и устранять повреждения под сильным огнем противника. Беспредельное мужество, стойкость, сила духа и любовь к Родине помогли ей героически выдержать тяжелые жизненные испытания. Военная судьба забрасывала ее в разные уголки мира. Она принимала участие в боевых операциях по ликвидации бандгрупп и других преступных элементов на Северном Кавказе и Казахской ССР. С 09.08 1945 по 03.09.1945 принимала участие в войне против Японии в составе 44 стрелкового полка ВВ НКВД 2 Краснознамённой армии 2 ПФД. Но и в дали от любимой Родины она честно и отважно выполняла свой воинский долг.

Награды: за героизм и мужество, проявленные в годы войны Анастасия Михайловна была награждена медалями «За победу над Германией», «За ликвидацию бандитских групп на Кавказе», «За победу над Японией», а также юбилейными медалями.

После войны Анастасия Михайловна долгие годы проработала в районной больнице бухгалтером, 14 лет – главным бухгалтером. Умерла в 2016 году.

*Сергеев Павел Сергеевич родился 9 июня 1922в деревне Куюк Ерыкса Мамадышского района.*

*Совсем юным, он отправился на фронти попал в 24 линейно-инженерную батарею. Он служил телефонистом-связистом, и его перебрасывали с одного фронта на другой. Павлу Сергеевичу довелось служить в 197 отдельном стрелковом полку, в 973 отдельном полку связи. Он воевал под Брянском, принимал участие в битве за Сталинград, освобождал Польшу. Павел Сергеевич не раз смотрел смерти в глаза. После войны он ещё служил в армии до ноября 1946 года в 173 отдельном строительном батальоне и в 16авиастроительном полку в должности рядового повара-инструктора, где учил молодых солдат готовить пищу.*

*Послевоенная судьба ветерана связана со строительством. Где бы ни работал, ветеран всегда относился к своим профессиональным обязанностям добросовестно. Под его руководством в районе встали в строй многие объекты, помолодели старые. Он работал в МСО, в ПМК-90. Павел Сергеевич участвовал в строительстве многих зданий в Таканышском районе,в п. Кукмор и Кукморском районе, таких как здание райкома в Таканыше, Дом культуры в п. Кукмор, мост в Большом Кукморе. За строительство здания районного Дома культуры он был отмечен Почетной грамотой. Умер в 2015 году.*

*Награды: Ветеран награждён орденом Отечественной войны II степени, медалями "За боевые заслуги", "За победу над Германией", "За участие в ВОВ 1941-1945г.", "За участие в героическом штурме и взятии Берлина" и юбилейными медалями.*

Закиев Шакир Закиевич родился 29.06.1925 в дер. Березняк Кукморского района Татарской АССР. В январе 1943 году был призван в ряды Советской Армии и служил пулемётчиком в в/ч 3636, с мая 1943 года – стрелком. Шакир Закиевич принимал участие в войне против Японии.

Награды: Медаль «За победу над Японией», 12.06.1946

Орден «Отечественной войны II степени», 11.03.1985

Медаль «Жукова», 19.02.1996

В послевоенные годы работал в райпищекомбинате, в сельпо возчиком, с 1959 года до выхода на пенсию в 1985 году, трудился сушилщиком на валяной фабрике.

В нашем музее есть экспозиция, которая называется «Боевые грозовые». На экспозиции представлены боевые награды: Орден Отечественной войны -3 степени, значок «Фронтовик», Юбилейные медали к 30,40 – летию Победы, книжка красноармейца, награды участника ВОВ Самигуллина Абдуллы Самигулловича.

В Музее представлены керосиновая лампа времен ВОВ, осколочная рубашка от гранаты; мина времен ВОВ; фронтовая пилотка; вилки времен ВОВ, немецкая фляжка времен ВОВ. Весной 2011 года три человека нашей школы побывали на раскопках в Новгородской области. Привезенные оттуда штык от винтовки Мосина, осколочная рубашка от гранаты; мина времен ВОВ являются ценными экспонатами.

Мины: Самым распространенным артиллерийским боеприпасом, встречающимся в местах сражений Великой Отечественной войны, были минометные мины. Минометные мины комплектовались взрывателями мгновенного действия высокой чувствительности, которые взводятся в момент выстрела.[5]

Винтовка Мосина магазинная винтовка, принятая на вооружение Российской Императорской армии в 1891 году. Активно использовалась в период с 1891 до конца Второй мировой войны, в этот период многократно модернизировалась. [5]

Ручная граната РГД-33. Сконструирована в 1933 году М. Г. Дьяконовым. Ручные гранаты применялись для поражения живой силы противника в ближнем бою, борьбы с танками и другими бронированными целями, разрушения прочных преград и укрытий полевого типа. [6] По назначению гранаты различались: противопехотные (осколочные), противотанковые, зажигательные и специальные (дымовые, осветительные и др.).

Осколочная граната. Осколочная граната по дальности разлета осколков делились на наступательные и оборонительные. [6]

Останки 132 мм реактивного снаряда «Катюша» . В 1939 года был разработан новый 132-мм осколочно-фугасный снаряд, получивший позднее официальное название М-13. По сравнению с авиационным РС-132 этот снаряд имел большую дальность полета и значительно более мощную боевую часть.[7]

Немецкий военный пенал, предназначенный для хранения 10 таблеток лозантина - средства для дегазации кожи при попадании на нее иприта - боевого отравляющего вещества кожно-нарывного действия. Каждому солдату выдавалось 4 пенала, которые положено было носить в нагрудных карманах. Пенал выпущен в 1940 году. Пенал входил в табельный комплект солдат Вермахта.[8]

В конце мы хотим сказать, мы должны знать и помнить о солдатах ВОВ. За одни сутки погибало 20869 наших солдат, а это значит на каждый метр земли приходится 15 солдат. Сгорели 1710 городов, 70 тысяч деревень, погибло более чем 27 *млн людей*, и остались инвалидами несколько миллионов людей. [9]

Из Кукморского района на войну ушли 18 тысяч человек. Из них 4, 600 солдат погибли, пропавших безвести 6000. На сегодняшний день остались только 57 ветеранов войны из 7 тысяч вернувшихся из войны.

*III. Представление проекта*

Анализируя деятельность по реализации проекта в течение 2 лет, можно сделать вывод, что интерес к историю края повысился. Мои одноклассники, друзья, волонтеры, школьники и дошкольники, населения Таишевского микрорайона с интересом слушают наши выступления. Мы проводим выездные экскурсии и представляем наш музей на разных мероприятиях. Значит, наш проект актуален и представляет собой интерес.

*Список литературы*


1. Матрусов И.С. Школьное краеведение и его задачи. /Краеведческая работа в школе: Тезисы докладов к конференции по проблемам краеведения и охраны окружающей среды в работе школы и педвузов, 1974, часть 4. – М. : 1974 с. 3
2. Сейненский А.Е. Родной край: страницы истории. В помощь педагогу-краеведу. – М. : 1994
3. Тверская Д.И. Музей как научно-исследовательское учреждение. /Сборник научных трудов Музея революции: Музей-культура - общество – М. : 1992 с. 61 - 90
4. Туманов В.Е. Школьный музей. Методическое пособие. М. : ЦДЮТ и К, 2002, с. 154
5. ru.wikipedia.org
6. feldgrau.info
7. operation-barbarossa.narod.ru
8. archeology.flybb.ru
9. beriozka-rus.livejournal.com›


## АВЫЛ ТАРИХЫ – УРАМ ТАРИХЫ


*Хасаншин Булат Айратович, ученик 10 класса*
*Научный руководитель – Хасаншина Венера Масгутовна*
*МБОУ "Узякская СОШ", Тюлячинского муниципального района РТ*


Күп күргән, күп белгән гыйлем кешеләренең сөйләвенчә, кешенең исемендә аның җисеме, холкы-фигыле, эчке дөньясы чагылыш таба. Урам-тыкрыкларга кушылган исемнәр дә монда яшәүчеләрнең уй-гамәлләренә йогынты ясыйдыр, мөгаен. Һәрхәлдә, Ленин исемендәге тәҗрибә җитештерү хуҗалыгында нәкъ әнә шулай фикер йөртәләр кебек. Биредәге Үзәк бистәсендә фидакарь хезмәтләре белән дан-шөһрәт казанган шәхесләрнең исемнәрен урамнарга биреп мәңгеләштерү матур бер гадәткә әверелгән. Мөхтәрәм игенче,

җитәкче булып торган елларда хуҗалыкның данын бөтен республикага шаулаткан Габделхак Галиев, Татарстанның һәм Россиянең атказанган ветврачы Миңнехаҗи Шакиров, Социалистик Хезмәт Герое, ике тапкыр Ленин ордены, “Урак һәм Чүкеч” алтын медале иясе Гөлбикә Кәримова урамнары шул хакта сөйли.

Без Үзәк урта мәктәбе урнашкан урамның ни өчен шулай аталу тарихын ачыклауны максат итеп алдык. 1996 нчы елда авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре өчен төзеп тапшырылган урам башта Мәктәп урамы исемен йөртә.1999 нчы елда, биредә Г.Кәримовага хөкүмәт йорт җиткереп биргәч ,бу урамга Үзәк авыл җирлегенең №321 карары нигезендә Г.Кәримова исеме бирелә.

Сыер савучы Г.Кәримованың хезмәт юлы бездә зур кызыксыну уятты. Фәнни эшебезне язганда, түбәндәге бурычлар куелды:

- Г.Кәримова турында музей һәм матбугат битләреннән мәгълүмат туплау;
- интервью алу.

Теманың актуальлеге:

1. Авыл урамнан, ә урам хуҗалыктан башлана. Авыл тарихын өйрәнгәндә, урам тарихын өйрәнүне читтә калдырырга ярамый. Хөрмәткә лаек авылдашларыңның хезмәт юлларын өйрәнү, белү бик кирәк.

2. Күп кеше бәхетне шәһәргә китеп, яхшы эшкә урнашуда күрә. Чынлыкта исә, авылда торып, гап-гади савымчы булып та, олы дәрәҗәләргә күтәрелергә мөмкин.

*Беренче бүлек. Хезмәттә табылган бәхет*

Гөлбикә апаның нәсел тамырлары Теләче төбәгендәге иң борынгы авыллардан саналган Карашырмәдә. 1950 елда аның ата-анасы Үзәккә күчеп килә. 7 нче сыйныфны Орымширмәгә барып укып йөреп тәмамлый. Сыер савучыларга кызыгып карап торган Гөлбикәнең хыялы тормышка аша. 15 яше дә тулмаган кызны мал азыгы ташуга билгелиләр. Бөтен эш кул белән эшләнә. Яшь нәфис кулларга печәнен дә, фуражын да, дәү-дәү кабакларны да төяргә-бушатырга туры килә. Авыр эштән кан оешкан тәнен төннәр буе уып чыккан чаклары да була. Ләкин түзә кыз. Балачактан ук күңелендә йөрткән хыялы, шушы хезмәткә мәхәббәте белән генә көч бирә.

Сыер савучыларның берсе эштән китеп баргач, аннан калган савым сыерлар төркемен Гөлбикәгә тапшырырга булалар. Һәм ялгышмыйлар, уңган кыз тиз арада, фермада гына түгел, бөтен районда иң яхшы күрсәткечләргә ирешә башлый. Тырышлыгын да бик тиз күреп алалар. 20 яше тулган көннәрдә ул партиягә кабул ителә. Ул 1953 елдан 1993 елга кадәр Ленин исемендәге тәҗрибә-җитештерү хуҗалыгында сыер савучы булып эшли. 1971-1975 елларда һәр сыердан уртача 5 мең литрдан артык сөт савып ала. Югары күрсәткечләре өчен аңа Социалистик Хезмәт Герое исеме бирелә (1971), ике тапкыр Ленин ордены (1966, 1971), “Урак һәм Чүкеч” алтын медале (1971), Почет грамоталары белән бүләкләнә. 80-90 елларда да аның исеме Мактау тактасыннан төшми. КПССның XXV съезды делегатына СССР Халык хуҗалыгы казанышлары күргәзмәсендә дә катнашырга туры килә. Өскәрәк үрмәләргә, җайлырак тормышка күчәргә менә дигән мөмкинлекләр бит болар. Тик Гөлбикә Кәримова үз эшенә тугрылыклы калган, беренче көннән алып лаеклы ялга чыкканчыга кадәр фермада хезмәт куйган. Нилектән шулай, аңлашылмый кебек? Барысына да балачак хыяллары сәбәпче. Ул аларга хыянәт итмәгән.

Икенче бүлек. “Хезмәт кешесенең кадере бетмәсен иде.”

Җир йөзенә кеше хезмәт итәргә килә. Хезмәт белән бәйле тормыштан үзенә тәм табып яши. Кешене кеше итүче дә, яшәешенә мәгънә, көч бирүче дә – хезмәт. Ул кешене кыргыйлыктан, караңгылыктан бу якты дөньяга – акыллы кешелеккә алып чыккан.

Электән үк безнең ата-бабаларыбыз хезмәтне үзләренең изге, бөек бурычлары итеп санаганнар. “Мең ел яшәрдәй кәсеп ит”, “Кешенең көче – эшендә”,“Эш сөйгәнне – ил сөяр”, “Һөнәрле кеше – бәхетле кеше”, “Агач – җимеше белән, кеше эше белән матур”, дигәннәр алар. Әйе, тырышып, җиренә җиткерелеп башкарылган һәрбер эш зур хөрмәткә лаек. Ул хезмәт зурмы, кечкенәме – иң мөһиме – кешеләргә файдалы булсын. Үзеңне төрле һөнәр иясе урынына куеп карасаң, кайберләре турында уйланып каласың. Үз-үзеңә сорау бирәсең:

“Бу һөнәр гаять авыр, аны башкарырга минем көчем, сабырлыгым җитәрме?” Әлеге хезмәтне башкаручыга сабырлык та, түземлелек, куәт тә кирәктер бит?! Менә шундый һөнәрләрнең берсе – сыер савучы.

Фәнни эшне башкарганда, Гөлбикә Кәримованың үзен күреп сөйләшергә туры килде: “Һәр эштә дә тырышлык, алда торган бурычны аңлау, хезмәтеңне ярату, аны ихлас күңел белән башкару таләп ителә. Шулай булмаганда, нинди яхшы сыерның да бозылуы мөмкин. Терлек тә ягымлы булуны ярата. Аны кычкырып ярсыту, кыйнау һич ярамый. “Девятка” кушаматлы сыердан туган бозауны һич онытасым юк, үз баламдай тәрбияләдем. Һаман да күз алдымда тора. Эшемне яратып башкардым. Кышкы чорда да һәр сыердан бер пот сөт савып ала торган идем. Җиңел булды дип әйтә алмыйм. Иренмәскә кирәк. Иң элек сыерның җилемен әйбәтләп юып, тастымал белән корытып сөртә торган идем. Савуны төгәлләгәч, массаж ясый торган идем. Җыеп кына әйткәндә, сыерның сөте телендә һәм савучының кулында. Күп сөт алуга ирешү өчен ел әйләнәсе көрәшергә, бөтен эшне белеп, җиренә җиткереп башкарырга туры килде. Бервакыт хуҗалык җитәкчеләре: “Бөтен өмет синдә – малларга ашатырга фураж калмады, Гөлбикә. Син делегат кеше, абруең зур, бар Мәскәүгә, ничек итсәң ит, әмма табарга тырыш! Югыйсә дөрләп яначакбыз!” – дигәч, юлга чыгып китәргә туры килде. Туп-туры СССР Авыл хуҗалыгы министрлыгына барып кердем. Үземнең кем икәнлегемне аңлаткач, ике дә уйлап тормастан, кулыма 500 тонна фуражга рөхсәт кәгазе язып биргәннәр иде.

Безнең чорда тырышып эшләгәндә кадер-хөрмәт, ихтирам яулап була иде. Хәзер вәзгыять башкачарак. Без иртәгесе көннең якты, өметле буласына ышанып яшәдек. Һәм ул шулай булды да, тормышлар көннән-көн яхшыра барды. Бүген ни ашыйм, ни киям дисәң, шул бар. Муллык хөкем сөрә, Аллага шөкер. Хезмәт кешесенең кадере бетмәсен иде инде”.

1993 елдан лаеклы ялда булса да, Гөлбикә Кәримова һәрдаим игътибар үзәгендә. Авыл хуҗалыгы өлкәсендә үткәрелгән республикакүләм семинарларның да ансыз үткәне юк.

Мәктәпнең “Туган якны өйрәнү” музеенда данлыклы савымчыга бер зур почмак бирелгән. “Геройлар көне”ндә ел саен Г.Кәримова белән очрашу оештырыла. Г.Кәримова белән үткәрелгән әлеге очрашуларны укучылар көтеп ала. Авылның хөрмәтле кешесе бик теләп безгә үзенең уй-фикерләрен җиткерә: “Фидакарь хезмәт куеп яшәргә кирәк! Кем генә булсаң да, әгәр син үз хезмәтең белән кешеләргә кирәк икәнсең, илеңә-халкыңа кирәк икәнсең – син бәхетле! Синең хезмәтеңнән кешеләр канәгать икән, шат икән – син бәхетле! Ә гомереңне яраткан эшеңә багышласаң, чит җирләрдә туган ягыңны бер күрергә тилмереп яшәмәсәң – син икеләтә бәхетле!”

Йомгаклау

Хезмәтебезне язганда, мәктәпнең “Туган якны өйрәнү” музеена, авыл һәм район китапханәсенә, җирле үзидарәгә мөрәҗәгать иттек. Фәнни эшебезне төгәлләгәндә, урамга исем бирелү тарихын ачыклау барышында түбәндәге нәтиҗәләргә килдек:

1. Г.Кәримова – Үзәк бистәсенең горурлыгы, данлыклы савымчысы, күренекле шәхесе. Ул киләчәк буыннарга өлге, урамның нуры булып тора. Аның Үзәк тарихында эз калдырырлык уңышлары күп.

2. Бу урамның исеме җисеменә туры килә. 14 хуҗалыкның 12сендә авыл хуҗалыгы тармакларында мактаулы һөнәр ияләре ягъни Гөлбикә апа дәвамчылары көн күрә.

3. Авыл тарихы – урам тарихы. Үзәк бистәсенең күп кенә урамы танылган сыер савучы, терлекче, ветеринар, игенче исемен йөртә. Киләчәктә бистәнең бүтән урам исемнәренең килеп чыгышын тикшерергә кирәк дигән фикер туды. Хезмәт Кызыл байрагы ордены кавалеры Фәридә Әүхәдиева, Татарстанның һәм Россиянең атказанган ветврачы Миңнехаҗи Шакиров урамнары да фәнни-тикшеренү эшенә кызыклы объект булып торалар.

*Кулланылган әдәбият:*


1. Хәлиуллин И. Теләче йолдызлыгы: Тарихи-публицистик очерклар.- Казан: Татар.кит.нәшр., 2006.

2. “ОПХ им.Ленина 70” буклеты.

3. Сверигин Р. Туган ягым – Теләче. Казан: "По городам и весям" нәшрияты, 2003.
4. "Знамя Победы" газеталары.
5. "Җиңү байрагы" газеталары.
6. Музей альбомы "ОПХ им.Ленина на страницах печати"

## АРБОР АВЫЛЫ ТОПОНИМИКАСЫ

*Шайхиева Язгуль Ришатовна, ученица 7 класса*
*Научный руководитель – Шайхиева Гелүса Саматовна*
*МБОУ "Арборская СОШ", Баотасинского муниципального района РТ*

Безнең авыл бик борынгы авыл, ул кайчан барлыкка килгән һәм аны ни өчен шулай дип атаганнарын әлегә төгәл белеп бетермим. Боларны ачыклау өчен мин үзем бераз гына тикшеренү эшләре алып барырга булдым. Минем уйлавымча, авылымның кайбер урыннарның атамалары аша туган якның тарихын ачыкларга була. Шуңа күрә "Арбор авылы топонимикасы" дигән эзләнү эше сайлавым да практик яктан зур әһәмияткә ия булган актуальлекне раслаучы факт.

Эзләнү эшемнең тикшерү объекты – авылның географик объектлары, табигый ландшафты; тикшерү предметы – авылның барлыкка килүен, яшәү рәвешен чагылдырган тарихи чыганаклар, язмалар, истәлекләр; тикшерү нәтиҗәсе – материаллар туплау, урыннарның исемнәренең мәгънәсен өйрәнү, тикшерү методлары – тарихи чыганакларны укып өйрәнү, чагыштыру, анализлау.

Эзләнү эшемнең максаты: Арбор авылы тирәсендәге топонимикаларны җыю, өйрәнү, аларның тарихын, килеп чыгышын ачыклау һәм аларны укыту-тәрбия эшендә куллану. Эшкә түбәндәге бурычлар куелды:

1. Тикшерү объектларын өйрәнү;
2. Топонимик исемнәрнең килеп чыгышын ачыклау;
3. Тирә-юнебезнең топонимикасының сүзлеген төзү.

Тикшерү объекты: авылның географик объектлары, табигый ландшафты. Эшемне башкару өчен эзләнү, мәгълүмат чыганакларын өйрәнү методларын кулландым.

Төп тикшеренү нәтиҗәсе – материаллар туплау, урыннарның исемнәренең мәгънәсен өйрәнү.

*Бүлек 1 Авылым турында*

Дөрестән дә, Арбор авылы табигатьнең бик матур почмагында, биеклеге 170-190 метр булган калкулыклы тигезлектә урнашкан. Тирә-юне урманнар. Тау битләреннән, урман аланнарыннан челтер-челтер чишмәләр ага. Һәр урман, болын, һәр чишмәнең үз атамасы бар.

Арбор авылы Вятка һәм Иләт елгалары арасындагы субүләр авышлыгында Татарстан Республикасы Казаннан 120км. ераклыкта төньяктарак урнашкан. Авыл Арборка елгасының уң як ярына урнашкан һәм елга буенча 2 км тирәсе озынлыкка сузылган. Елга үзәненең ике ягы буйлап биек булмаган калкулыклар (үрләр) күтәрелә. Авыл шул үрләр арасындагы уйсулыкка урнашкан. Арбор исеменең чыгышы элеккеге Урбар исеменә бәйле, "Үр" бар дигән сүздән барлыкка килгән. Тора-бара бу сүз әйтелеше Арбор булып үзгәрә.

Арбор территориясенең геологик төзелеше югары Казан һәм югары Пермьнең татар ятмаларыннан тора. Алар дүртенчел чор токымнары белән капланган. Югары Казан ятмалары доломитлардан, известьташлардан һәм комташлардан тора. Аларда балчык, мергель, аргиллит катламнары күренә. Ятмаларның калынлыгы 25м дан 44м га кадәр җитә. Татар ятмалары балчык, комташ һәм известьташлардан тора. Аларга урыны-урыны белән мергель үтеп кергән. Ятмаларның калынлыгы 7м дан 30м га кадәр. Аларны каплап өстәрәк ятучы, 2м дан 10м га кадәр калынлыктагы дүртенчел чор

токымнары балчык һәм кызыл балчыктан тора. Дүртенчел чор токымнары туфрак, үсемлек белән капланган. Авыл һәм күмәк хуҗалык җирләре калкулы тигезлеккә урнашкан. Калку урыннар төрле зурлыктагы ерымнар белән кискәләнгән. Ерымнар җил һәм су эрозиясе тәэсирендә зураялар, тирәнәяләр.

Грунт сулары 3-8 метр тирәнлектә ята. Җир асты суларын йөртүче катлам известьташ, доломит һәм комташлардан тора. Язгы чорда су өслеге 1 – 1,5 метрга кадәр күтәрелергә мөмкин.

*Бүлек 2. Топонимика нәрсә өйрәнә?*

Топонимика фәне географик исемнәрнең мәгънәсен, килеп чыгышын, үзгәрешен, хәзерге вакыттагы торышын, язылышын, әйтелешен өйрәнә.

Топонимика география фәне белән бик тыгыз бәйләнештә: ниндидер объектны өйрәнү өчен, аны бик яхшылап күзалларга кирәк. Тарих белән бәйлелеге: халык күченеп китә, ләкин алардан калган елга, күл, тау атамалары алардан соң күченеп килгән халык хәтерендә сакланып кала. Күп кенә географик атамалар үзендә тарихи вакыйгаларны саклый. Шул ук вакытта топонимика ул – ономастика да. Ономастика – лингвистиканың ялгызлык исемнәренең тарихын, килеп чыгышын өйрәнүче бер бүлеге.

Топонимия – нинди дә булса территориянең атамалар җыелмасы.

Топонимиканы төрләре буенча төрле классларга бүләләр.

Ойконимнар – торак пунктларның атамасы.

Гидронимнар – сулыклар атамасы.

Оронимнар – таулар, калкулыклар атамасы.

Дримонимнар – урманнар атамасы. Гадонимнар – урамнар исеме.

*Бүлек 3. Гидронимнар: елгалар, инешләр, чишмәләр.*

Арбор (Арборка) елгасы – исеме монда безнең авылдан күпкә алданрак нигезләнгән, марилар яши торган Арбор авылыннан алынган – димәк, Арбор авылы янынннан ага торган елга. Мари Иле Республикасының Мари Төрәк районы җирлегендәге Зур Карлыган авылы янындагы чишмәдән башлана һәм, көнбатыштан көнчыгышка таба бормаланып агып, җир асты һәм күп санлы чишмәләр белән суы белән тулыланып, Смәел авылыннан бераз түбәндәрәк Шушма елгасына кушыла. Озынлыгы 27,2 км, су туплау мәйданы 13180 квадрат-метр. Иң тирән урыны 1,76 метр, иң киң урыны 10 метр. Елганың ярлары урыны-урыны белән үтә куе тал-тирәкле. Язларын алар җансызга да җан өрә торган сандугачлар моңына күмелә. Монда күп төрле елга балыклары, ондатралар бар, язын кыр үрдәкләре, челәннәр кайта. Тугайлары мул печәнле, камыш, саз үләннәре үсә.

Арборка елгасы – авылыбызның күрке, горурлыгы, яшәү чыганагы. Безнең бурыч – аны күз карасы кебек саклау, пычратмау, кадерсезләмәү.

Кләтиңгәр елгасы – ике як ярын хасил итүче сөзәк үрләре чикләвек һәм артыш куаклары белән капланган, түбән өлешендә ялангач булган зур коры елга. Куныр ягындагы басулардан башланып, авылның көньчыгыш өлеше тирәсендә Арбор елгасына сул кушылдык булып тоташа. Елганың урта өлеше үтә тирән, шуңа күрә бу өлеше халык арасында Тирән елга исеме белән билгеле. Авыл өлкәннәре егерменче гасыр башларында ярларыннан чишмәләр агып чыкканлыгын сөйлиләр иде, бүген алар юк инде. "Эңгәр" сүзе кушылу исеменең марилардан калганлыгына ишарәли. Кләтиңгәр елгасы Арбор елгасы белән кушылган урында борынгы чорда киң мәйданда сазлыклар булган. Авылыбызга нигез салучы борынгы кешеләр нәкъ менә шушы урынга нигез корганнар.

Мөниңгәр инеше – исеме мари теленнән алынган, сазлыклы елга мәгънәсен бирә. Кәтәй урманының түбән очындагы мул сулы чишмәдән (аны Гөлкәй чишмәсе дип тә атыйлар) агып чыга торган инешчекнең киңлеге 0,8-1,5 метр, тирәнлеге 0,5 метр. Урман читендәге уйсулыкка таралып, сазлык хасил итә. Бүген ул сазлык юк инде. Инеш әнә шул сазлыктан агып чыга, чишмә, җир асты һәм явым-төшем сулары белән туенып Фәхри тавы итәге буйлап агып төшеп, авылны Арбор һәм Мөниңгәр өлешләренә бүлеп, Арбор елгасына кушыла. Бу инешчектә су сыешлыгы 418$м^2$ булган плотина (буа) төзелгән. Ул шактый

еллар басуларны сугару өчен файдаланыла. Буада карп, бәртәс һәм башка балыклар күп.

Өлшеңгәр елгасы – ике як сөзәк ярлары печәнлекле булган зур коры елга. Бүгенге көндә көтүлек итеп файдаланыла. Исеме марилардан калган.

Шәми елгасы – Өлшеңгәр елгасына охшаш табигатьле зур коры елга. Бүгенге көндә шулай ук көтүлек итеп файдаланыла. Авылыбызның революциягә кадәр яшәгән бер Шәмсетдин исемле кешенең кушаматы белән аталган.

Мари (Рушенер) елгасы – Мещан урманыннан башланып, бормалануларсыз Арбор елгасы буендагы үзәнлеккә төшә торган тәбәнәк-сөзәк ярлы коры елга. Татарстан һәм Мари Иле Республикаларының чиге буйлап уза. Елга ярыннан 1985 елда Уренгой-Ужгород нефть үткәргеченең ике параллель магистрален тоташтыручы нефть үткәргече сузылды. Бу аның ландшафтын шактый үзгәртте. Елганың ярында мәҗүси мариларның борынгы зираты саклана.

Урта елга – табигате, рельефы белән Кәтәй урманын кабатлый. Фәхри белән Кәтәй арасындагы елгалыктагы урман булу сәбәпле шулай дип атыйлар.

Коры елга - авыл башында урнашкан. Элек монда су булмаган, ә хәзер инде аз гына су төшә башлаган.

Гөлкәй чишмәсе (Кәтәй чишмәсе) – кайчандыр Гөлкәй исемле бай хатын безнең якларга килгән булган. Ул кирпеч заводы салдырган, чишмә казыткан. Кирпеч сугарга ярындагы кызыл балчыкны ташыганнар. Әлеге чишмә Кәтәй урманында урнашкан. Су авыш урыннан ташлы көрән, кызгылт балчык катламы арасыннан өскә чыга.

Тазлар (Сабантуй) чишмәсе – Арбор тавы итәгеннән көрән балчыклы катлам арасыннан, төптән басымсыз агып чыгып чишмә хасил итә. Чишмәгә бетон божра куелган. Улакның икенче башы агач бурага чыга. Җәйге чорда су чыгымы бер минутка 18 литр, катылыгы 4,0 ммоль/дм$^3$. Чишмә суы 100 метр чамасы юл үтеп Арборка елгасына кушыла. “Тазлар” исемен үзен карап-төзекләндереп тоткан авыл кешеләренең кушаматыннан алынган. Истәлек-риваятьләрдә ул гаилә ирләренең барысының да пеләш (таз) булуы турында сөйләнә. Хәзерге көндә чишмәдән ерак түгел урындагы елга үзәнендә авылның сабантуйлары уза. Шул сәбәпле күбрәк “Сабантуй чишмәсе” дип атыйлар. Бу чишмәнең шифалы йомшак суын илебезнең бик ерак төбәкләреннән кайтып кунак булган бик күпләр авыз итәләр һәм суының тәмлелеген мактап бетерә алмыйлар.

Кызыл яр чишмәсе – Арборка елгасының текә, биек сул яры итәгенә урнашкан. Яр кызыл комташтан һәм известьташтан тора. Су известьташ катламы арасыннан астан, басымсыз чыгып чишмә хасил итә. Су чыгымы 1 минутка 6 литрга тигез. Чишмәгә урыныннан чыгып исем биргәннәр.

Әнвәрҗан чишмәсе – Арбор елгасының сул, биек, текә ярында урнашкан. Чишмәнең су чыгымы 1 минутка 10 литр тәшкил итә, катылыгы 5,6 ммоль/дм$^3$. Су металл торба аша уң ярга чыга. Торбадан чыккан су 7 метр юл үтеп Арбор елгасына агып төшә. Моннан 50 еллар чамасы элек язгы ташу чорында барлыкка килгән. Текә яр көрән һәм кызгылт балчык, известьташ катламнардан тора. Чишмә Гаязетдинов Әнвәрҗан абый йортыннан ерак тугел һәм аны элегерәк Әнвәрҗан абый, аннан аның уллары карап, төзекләндереп торалар. Шуңа күрә чишмә аның исемебеләнатала. Чыганак тирәсендә зирек, тал, каен, миләш, усак агачлары үсә.

Мөниңгәр чишмәсе – Арборка елгасының сул үзәнендә, калкулык итәгендә урнашкан. Калкулыкта нарат агачлары, ә чишмә янында каеннар үсә. Су төптән, басымсыз известьташ катламыннан чыгып бетон божра эченә җыела һәм торба аша чыга. Аннан чыккан су 58 метр ара үтеп Арборка елгасына коя. Чишмәнең су чыгымы 1 минутка 8 литр, катылыгы 6,4 ммоль/дм$^3$. Соңгы елларда чишмәне бик матур зур будка белән әйләндереп алып, янәшәсенә чәчәкләр утыртып, карап чистартып торалар.

Гайнан чишмәсе – Мөниңгәр инешенеңуң як ярында текә яр буйлап саркып чыккан суга Халиуллин Гайнан торба урнаштыра. Соңгы елларда чишмәнең суын торба аша

инешнең сул ярына Садыйк посадкасы ягына чыгарып, калайдан будка ясап, матурлап куйдылар. Көтүчеләр, юлаучылар өчен элеге чишмә аеруча уңайлы.

Айдар чишмәсе – калкулык итәгенә урнашкан. Чишмә янынnda каен, тал агачлары, ә калкулыкта наратлар үсә. Су ташлы көрән балчык арасыннан чыга һәм акрын гына Арборка елгасына кушыла. Бу урында элек буа һәм су тегермәне булган. Тегермән янында тегермәнченең йорты торган. Инде күптән алар юк. Моннан 30 еллар элек чишмә дә юкка чыккан булган. Аны авылдашыбыз, көрәш буенча дөнья чемпионы Хәйретдинов Айдар кабат казып чыгарды. Хәзерге вакытта чишмәне аның исеме белән атыйбыз.

Курамьял чишмәсе – Арборка елгасының сул ягына, калкулык итәгенә урнашкан. Калкулыкта нарат агачлары. Ә итәгендә нарат, каен, карагай агачлары һәм сазлык үсемлекләре үсә. Чишмә суы астан басымсыз чыгып чокырлы урынга җыела. Су җыела торган урын такта белән әйләндереп алынган һәм 6 метр озынлыктагы торба куелган. Торбадан аккан су 6-7 метр араны һтә һәм акрынлап торфлы, дымлы туфракта үскән камышлар арасында югала. Чишмәнең су чыгымы 1 минутка 7 литр. Калкулык Курамьял тавы дип атала, чишмәгә дә шул исем бирелгән.

Фәхри чишмәсе – 1940 елларда урман каравылчысы булып эшләгән Фәхри исемле кеше исеме белән аталган. Ул чишмәне казыган һәм тирә-юненә агачлар утырткан. Фәхри урманы уртасыннан тирән елга үтә, әлеге елга башында, сөзәк урында чишмә урнашкан. Чишмә суы басымсыз чыгып кешеләр тарафыннан ясалган кечкенә такта бура эченә җыела һәм тимер торба аша тышка чыга. Чишмә суы елга төбеннән агып бераз юл үткәч, җиргә сеңеп юкка чыга. Фәхри чишмәсеннән печән чабучылар, җиләккә йөрүчеләр файдалана.

2016 нчы елда авылыбыз “Чиста су” проекты аша һәрбер өйгә краннан чиста, йомшак су килүгә иреште (катылыгы 2,7 ммоль/дм$^3$). Фәхри чишмәсе янында скважина бораулап, авылны су белән тәэмин иттеләр.

*Бүлек 4. Дримонимнар: урманнар, каенлыклар.*

Кәтәй урманы – тирән коры елганың ике ярын биләп үскән зур булмаган катнаш урман. Исеме шушы урманга бәйле билгесез борынгы кеше исеменнән алынган. Урман – авыл халкының ял итә торган урыны. Андагы бер бик зур аланда ел саен, авыл сабантуеның икенче көнендә “Урман сабантуе” үткәрелә.

Мещан урманы – Мари елгасының башланган җирендәге кечкенә катнаш урман. Янәшәсендә генә шул ук исемдәге чикләвек куаклыгы да бар. Бикбулат авылының нигезләнүенә сәбәпче булган Казан мещаннары исеме белән бәйле.

Авылыбызның Субаш ягы басулары түрендә гаять матур, каен җиләгенә, чикләвеккә бай каенлыклар бар.

Атау каенлыгы - юл өстендәге урманчыкта Атау исемле кеше адашы үлгән. Шуңа күрә каенлыкны “Атау каенлыгы” дип атыйлар.

Әкәй каенлыгы - бу урманчык янында бик салкын буранлы көндә күрше Мари авылы хатыны адашып өшеп үлгән. Мари хатын-кызларын бездә әкәйләр диләр. Бу каенлыкны шушы вакыйга белән бәйләнешле рәвештә “Әкәй каенлыгы” дип атыйлар.

Сыер хуты каенлыгы - көтү төш чорында шунда төшлеккә төшкән, исеме шуннан килеп чыккан.

Озын каенлык - урманчык тар озын булып сузылган, шуның өчен “Озын каенлык” дип атала.

Кара каенлык - төрле агачлар үсүче бу каенлык шактый куе, эченә керсәң караңгы һәм адашырдай зур урман булып тоела.

Мәхмүт каенлыгы – (Беткән каенлык)- бу каенлыкта Мәхмүт дигән кеше адашып йөргән. Авыл бабайлары аны күреп чыгарып кайтарып җибәргәннәр. Соңырак бу каенлыкны бетереп, чәчү чәчәләр.Бүгенге көндә ул “Беткән каенлык” дип атала.

Садыйк посадкасы. Бу каен полосасы күренекле шагыйрь Гарифҗан Мөхәммәтшинның әтисе Мөхәммәтсадыйк бригадир булып эшләгәндә, аның җитәкчелеге

белән утыртылган. Г.Мөхәммәтшинның “Әтием каенлыгы” шигыре шушы каенлыкка атап язылган.

*Бүлек 5. Оронимнар: таулар.*

Арбор тавы – авылыбызның икенче төп күрке һәм бизәге. Риваятьләр хәтта авылыбызың исемен дә шушы тау белән бәйли. Ул шактый текә – биеклеге Арбор елгасы өслегеннән 85 метрга җиткән урыннары бар. Басу сулары агып төшүдән хасил булган ерганаклар аңа үзенә генә хас серлелек бирә. 1982-1987 елларда тауга нарат урманнары утыртылган.

Фәхри тавы – Мөниңгәр инеше буйлап сузылган сөзәк калкулык. Исеме авылыбызның билгесез бер шәхесе исеме белән бәйле. Артышлар күп үсә, җир җиләге мул була. Өске өлешендә Мөниңгәр инеше бассейнына кушыла торган коры елганы ике яклап иңләп үсә торган Фәхри урманына тоташа.

Алмагач тавы – элек, “Социализм” колхозы тауга алмагачлар утырткан, шуңа күрә бу тауны Алмагач тавы дип атыйлар, хәтта бүгенге көндә алмагачлары булмаса да, исеме сакланган.

*Йомгаклау*

Туган авылымның атамаларын өйрәнеп, мин шуны аңладым, топонимикаларны өйрәнү бик кызыклы һәм мавыктыргыч икән. Мин әле боларны өйрәнә генә башладым, барысына да ирешү - зур бурыч. Шулай итеп, авылымның топонимнарын өйрәнеп, шундый нәтиҗәгә килдем:

- Топонимиканың үзенчәлеге дә фин-угор пластына барып тоташкан татар исемнәрендә чагыла. Безнең якларның ойконимнары кызыклы һәм бик серле.

- Без Марий Эл республикасы һәм Киров өлкәсе белән чиктәш. Бу хәзерге топонимикага берничек тә йогынты ясый алмыйча кала алмый, чөнки һәр халык, һәр милләт үз формасын өсти. Шул ук вакытта, бүген дә ут күршеләр булып, бергә-бергә дус һәм тату яшәгән марилар белән тыгыз бәйләнешне дә күрсәтә.

- Эшебезнең нәтиҗәсе буларак территориябез буенча географик атамалар сүзлеге булдырдык.

Алга таба географик атамаларны җыю урыннарда, архив материалларына таянып алып барылачак. Кайбер объектларның исемнәре үзгәрүне дә анализлап китәргә мөмкин. Кайсы атамалар колхоз, совхоз, оешма исемнәреннән калган, ә кайсылары туган авылдан чыккан зур кешеләргә багышланган. Элеге материалны география, тарих, әдәбият дәресләрендә һәм шулай ук туган якны өйрәнү чараларында кулланырга була.

*Кулланылган әдәбият:*

1. А.А.Хуснутдинов “Схема территориального планирования Балтасинского муниципального района” – Казань, 2012 – 224 б.
2. Альбом “Арбор авылы”
3. Альбом “Челтер-челтер ага чишмә”
4. Г.С.Мөхәммәтшин “Урбар” – Казан, 2013. – 720 б.
5. З.Г. Хәлиуллина “Туган авылым бизәкләре” – Казан, 2010 – 48 б.

# *ҖӘЛИЛ ХӘЗРӘТ ФАЗЛЫЕВ – МИЛЛӘТЕМ ГОРУРЛЫГЫ*

*Шарипова Файруза Илнуровна, ученица 8 класса*
*Научный руководитель – Миннемуллин Айгиз Рафилевич*
*МБОУ Бурбашская СОШ", Балтасинского муниципального района РТ*

Җәмгыятьтә барган тирән үзгәрешләр әдәбият, дин, сәнгать мәсьәләләренә яңача карауны таләп итә. Китап укуга, әдәбият белән кызыксынуга, иҗат эшенә рухлануга, төрле информация чаралары һәм көндәлек матбугат белән мөстәкыйль эшләү күнекмәләре булдыруга, әхлак, эстетик зәвык формалашуга, туган якның үткәне, бүгенгесе һәм киләчәгенә кызыксыну уятуга, милли үзаң тәрбияләүгә әдәби туган як материалларын өйрәнүнең әһәмияте зур, дип саныйм мин.

Кеше, өйдән, ишек алдын үтмичә, олы юлга чыга алмый. Шуның кебекбезгә, укучыларга, туган як әдипләренең тормышы, эшчәнлеге белән танышмыйча, дөньякүләм танылган олпат шәхесләрнең иҗатын югары дәрәҗәдә күзаллау мөмкин түгел.

Республикабызның кайсы гына районында яшәсәк тә, туган ягыбызның үз төбәгенә генә хас булган кабатланмас матурлыгын күрсәтергә, бай тарихын сөйләргә, күренекле шәхесләре белән таныштырырга бурычлыбыз. Мин – мәгърур таулары, хәтфә болыннары, урман-күлләре, тырыш-уңган, хезмәт сөючән халкы белән дан тотучы Балтач районыннан**.**

Бүгенге язылачак язмамда, районыбыз, авылыбыз халкы тарафыннан зур ихтирамга лаек булган, яраткан язучыбыз, татар дин эшлеклесе, авыл хуҗалыгы белгече, икътисадчы һәм хаҗи-әкбәрҖәлил хәзрәт Фазлыевның тормыш юлы, иҗаты һәм аның иҗатын өйрәнү мәсьәләләре турында язарга телим.

*II. Төп өлеш*

Татарстан Республикасының баш Казые Җәлил хәзрәт Фазлыев Балтач районы Бөрбаш авылында 1956 нчы елда туа. Әтисе Васил, әнисе Маува совхоз эшендә булганлыктан, әби-бабай тәрбиясендә үсә. Бернәрсәдән дә курыкмаган, бары тик Аллаһ, аның кануннарын белгән әбисен ул еш искә ала.

*Үзара аралашыгыз! Йөзегез нурланыр, кальбегез чистарыр, ризыгыгыз киңәер (Хәдис).*Яшьтәшләре сөйләвенчә, яшьтән үк бик башлы, ярдәмчел була ул. Спортны бик ярата, сабантуй ярышларында беренчелекне бирми, 14 ел буе колгага бары тик ул гына менә. Бөрбаш урта мәктәбен "5"ле билгеләренә генә тәмамлап, авыл хуҗалыгы институтында укый, аны кызыл дипломга тәмамлый. Аспирантурага калырга тәкъдим итсәләр дә, монда аның үз планнары. Армиядә хезмәт итеп кайткач, 8 ел Балтач районының баш экономисты булып эшли. "Районның мактаулы экономисты" дигән исем бирелә.

*Кыйммәтсез, кечкенә генә әйбергә дә карап соклана белсәң, бәхет ачкычлары синең кулыңда булыр (Хәдис).*Туган авылында баш экономист булып эшли башлагач, күңелендә яңа хыяллар барлыкка килә. Аның балалар укытасы, хәреф танытасы, дин өйрәтәсе килә. 1988 нче елда мәктәптә гарәп хәрефләре белән укырга-язарга өйрәтә башлый, әкренләп балаларны намазга бастыра.

*Бәхет канәгать кеше яклы булачак (Хәдис).*Бик күп тырышлыклар куеп, Җәлил хәзрәт туган авылында мәчет төзетә. Кыш көннәрендә монда 100 дән артык шәкерт дәресләргә йөри, аның үрнәгендә Балтач районында мәчетләр төзи башлыйлар.

*Бәхетле кешеләр үзләренең елмаюлары һәм мәрхәмәте белән бөтен дөньяны үзләренә караталар (Хәдис).* Кечкенәдән башлы, юмор хисе булган, үз сүзен өзеп әйтә белүче Җәлилнең вәгазьләрен халык йотлыгып тыңлый, аңа тартыла башлый. Аның дини-тәрбияви фикерләре китап битләрендә дә урын ала. Бүгенге көндә аның егермеләп китабы дөнья күрде. Аның "Җәлил хәзрәт вәгазьләре", "Җәлил хәзрәт дәресләре", "Иманлы бала", "Иман вазыйфалары", "Ягез бер дога", "Йөз дә бер вәгазь" исемле китаплары басылып чыкты.

*Бөтен дөньяда кешеләр иминлектә, тынычлыкта, хөрмәт һәм мәхәббәттә булуын теләсәгез, гаиләгезне сөяргә өйрәнегез (Хәдис).*Җәлил хәзрәтне бәхетлеләрнең бәхетлесе дип атасак та, ялгышмабыз: гаиләдә тугрылыклы ир, 3 бала атасы, 7 оныкка бабай, энесе һәм сеңлесенә зур терәк ул. Уллары Булат һәм Алмаз үз гаиләләре белән авылда яши, ә кызы Айсылу этисе язган китапларга мөхәррирлек итә.

*Бәхетле кеше, эче сөенеч белән тулганга, бөтенесенә бәхет тели (Хәдис).* Аның тырышлыгын күреп, Татарстан президенты Минтимер Шаймиев югары бәяләде, шул елларда Татарстан Диния нәзарәте идарә әгъзасы, үз төбәгендә мөхтәсиб, берничә районга казый да булып сайлана.

*Яшә шулай, синең белән очрашканда кешеләр елмайсыннар, аралашканда бәхетләрен арттырсыннар (Хәдис).*Җәлил хәзрәтнең осталыгын күреп, Татарстан Диния нәзарәте аңа берләшү корылтаен алып баруны тапшыра. Ул аны җиренә җиткереп башкарып, җөмһүриятебездә танылу ала.

*Бәхетеңне арттырырга теләсәң, чиләгеңдәге чүбеңнән генә түгел, күңелеңдәге чүбеңнән дә котыл (Хәдис).* Республикабызның баш Казые Җәлил хәзрәт төрле авыл, шәһәрләрдә мәчет һәм мәдрәсәләр ачуда еш катнаша. Кайда гына барса да, үзенең тәрбияви-дини вәгазьләре белән халыкны яхшылыкка өнди.

*Үзе өчен һәйкәл куйдырырга омтылмаган кеше генә һәйкәлгә лаек (Хәдис).* Республиканың баш Казые Җәлил хәзрәтне Россиянең төрле өлкәләрендә дә күренекле шәхес буларак беләләр.

*Кешегә ярдәм итә алсаң, ярдәм ит, булдыра алмасаң, аның өчен дога кыл (Хәдис).* Барлык яктан да камил шәхесләр тәрбияләү өчен, мәктәбебездә беренчеләрдән булып әхлак дәресләре үткәрелә башлады. Без, укучылар, әлеге дәресләрне көтеп алабыз, яратып укыйбыз. Җәлил хәзрәт районыбызның һәм республикабызның әхлак укытучылары белән даими элемтәдә тора, аларга дини юнәлеш бирә, матди ярдәм күрсәтә.

*Кальбен иман өчен сафландырган, телен тугры сүзле кылган, күзен күңел күзе белән карауч иткән кеше уңышка ирешә (Хәдис).*Менә инде 10 ел рәттән мөселман балалары өчен сабан туе үткәрелә. Аның төп оештыручысы Җәлил хәзрәт Фазлыев. 2015 елны әлеге бәйрәм Бөтен Рәсәй күләмендә зурлап үткәрелде. Төрле регионнардан килгән балалар бәйрәмнең оештырылу дәрәҗәсенә сокланып, бу елны да килү турында хыялланып кайтып киттеләр.

*Бәхетле кеше исә гел хәрәкәтләнә һәм шуның бәрәкәтен татып сөенә (Хәдис).* Республикабыз җитәкчеләре дә Җәлил хәзрәт фикерләренә таяна, киңәшләренә колак сала.

*Эй кешеләр, изгелекләрдә узыша-узыша ярышыгыз (Хәдис).* Туган авылыбызда да Җәлил хәзрәтнең дәрәҗәсе зур. Аның кылган изгелекләрен санап бетергесез. Аның ярдәме белән авыл урамнары төзекләндерелде, күперләр салынды, 2 катлы мәктәп бинасы балкып утыра, чишмәләр яңартылды. Авыр тормышлы гаиләләргә дә даими ярдәм итеп тора. Гомумән, авылыбыз халкы аның ярдәмен тоеп яши.

*Әй мөселманнар, башка дин әһелләрен сүкмәгез, аларга сүз тидермәгез (Аять).*Башка милләт халыклары белән дус һәм тату яшәү максатыннан, төрле дин әһелләре белән дә еш очрашулар була. Күптән түгел генә Җәлил хәзрәт Христиан дине вәкиле белән дә халыклар арасында дуслыкны ныгыту, ришвәтчелек, терроризмга каршы көрәш чаралары турында фикер алыштылар.

*Һәрбер көнне бәхетле бәйрәм көненә яки хәсрәтле хәтер көненә әйләндерү кешенең үз кулында (Хәдис).*Әле күптән түгел генә халыклар арасындагы милли дуслыкны үстерүдәге хезмәтләрен исәпкә алып, Татарстан Республикасы президенты Рөстәм Миннеханов Җәлил хәзрәтне Рәхмәт хаты белән бүләкләде. Район халкы өчен эшләгән изге гамәлләре өчен, 2015 нче елда Балтач районының “Мактаулы гражданины” исеменә лаек булды.

*III. Йомгаклау*

*Бәхетле булу халәте Алладан сорауда түгел, ул биргән нигъмәтләрнең кадерен белеп, шөкер итүдән гыйбарәт (Хәдис).* Җәлил хәзрәтнең вәгазьләрен күптән ишетеп беләм, рәхәтләнеп тыңлыйм. Ул бик күпләрнең күңеленә иман нуры салучы, туры юл күрсәтүче

остаз, чөнки туры юлның ахыры шатлык, җәннәт белән бетә. Менә шушылай яшәүләребезнеАллаһ Раббыбыз барчабызга да насыйп кылса иде!

Йомгак ясап әйткәндә, Җәлил хәзрәт Фазлыев һәрвакыт бөтен җаны-тәне белән үзенең укучылары язмышы өчен янып яши, аның тормыш-көнкүрешен яхшырту турында кайгырта, телебез, милләтебез, гореф-гадәтләребезне саклау һәм үстерү өчен тырыша.

*Кулланылган әдәбият*

1.Балтач энциклопедиясе – Казан: 2010. – 536 б.
2.Фазлыев Җ. Әти-әниләргә нәсыйхәт: тәрбия турында – Казан: Иман, 2011. – 112 б.
3. Фазлыев Җ. Җәлил хәзрәт дәресләре – Казан: 1999. – 184 б.

# ИССЛЕДОВАНИЕ СПЕКТРАЛЬНЫХ ЛИНИЙ ПАРОВ МЕТАЛЛОВ И ГАЗОВ ПРИ ПОМОЩИ ШКОЛЬНОГО ДВУХТРУБНОГО СПЕКТРОСКОПА

*Абдуллин Данияр, ученик 9 класса,*
*Научный руководитель: Леонтьев Вадим Анатольевич*
*МБОУ «Гимназия им. К. Ф. Шакирова с. Большой Сардек»*
*Кукморского района РТ*

Цель: Исследование спектральных линий паров металлов и газов при помощи школьного двухтрубного спектроскопа.

Задачи:

1. Изучить метод спектрального анализа.
2. Выяснить физическую природу спектров различных типов.
3. Изучить устройство и принцип работы школьного двухтрубного спектроскопа.
4. Изучить руководство по эксплуатации учебных спектральных труб.
5. Ознакомиться с правилами безопасного пользования высоковольтным генератором.

Исследование линейчатого спектра вещества позволяет определить, из каких химических элементов оно состоит и в каком количестве содержится каждый элемент в данном веществе.

Метод определения качественного и количественного состава вещества по его спектру называется спектральным анализом. Спектральный анализ широко применяется при поисках полезных ископаемых для определения химического состава образцов руды. В промышленности спектральный анализ позволяет контролировать составы сплавов и примесей, вводимых в металлы для получения материалов с заданными свойствами.

Достоинствами спектрального анализа являются высокая чувствительность и быстрота получения результатов. С помощью спектрального анализа можно обнаружить в пробе массой $6*10^{-7}$ г присутствие золота при его массе всего $10^{-8}$ г. Определение марки стали методом спектрального анализа может быть выполнено за несколько десятков секунд.

Спектральный анализ позволяет определить химический состав небесных тел, удаленных от Земли на расстояния в миллиарды световых лет. Химический состав атмосфер планет и звезд, холодного газа в межзвездном пространстве определяется по спектрам поглощения.

Изучая спектры, ученые смогли определить не только химический состав небесных тел, но и их температуру. По смещению спектральных линий можно определять скорость движения небесного тела.

Спектральный анализ. Спектральный анализ - физический метод качественного и количественного определения атомного и молекулярного состава вещества, основанный на исследовании его спектров.

В основе спектрального анализа лежит изучение строения света, который излучается или поглощается анализируемым веществом. Методы спектрального анализа делятся на эмиссионные (эмиссия — испускание) и абсорбционные (абсорбция — поглощение).

Эмиссионный спектральный анализ основан на способности возбужденных атомов излучать. Если анализируемое вещество испарить, например, в электрической дуге, т.е. сообщить его атомам энергию и привести их в возбужденное состояние, то вещества начинает светиться. Атомы каждого элемента испускают излучение определенных длин волн, что позволяет определить, какие элементы входят в состав анализируемого вещества. Поскольку интенсивность излучения зависит и от количества излучающих атомов, то по наличие и положению полос делают вывод о составе вещества (качественный анализ),а по интенсивности полос определяют(с помощью калибровочной кривой)содержание отдельных элементов(количественный анализ )

Абсорбционный спектральный анализ основан на способности молекул и атомов поглощать электромагнитное излучение. Он широко применяется для анализа раствора и позволяет выявить состав раствора и концентрацию компонентов.

Рассмотрим схему эмиссионного спектрального анализа. Для того чтобы вещество излучало свет, необходимо передать ему дополнительную энергию. Атомы и молекулы анализируемого вещества переходят тогда в возбужденное состояние. Возвращаясь в обычное состояние, они отдают избыточную энергию в виде света. Характер света, излучаемого твердыми телами или жидкостями, обычно очень мало зависит от химического состава и поэтому его нельзя использовать для анализа. Совсем другой характер имеет излучение газов. Оно определяется составом анализируемой пробы. В связи с этим при эмиссионном анализе перед возбуждением вещества его необходимо испарить.

Испарение и возбуждение осуществляют в источниках света, в которые вводится анализируемая проба. В качестве источников света используют высокотемпературное пламя или различные типы электрического разряда в газах: дугу, искру и др. Для получения электрического разряда с нужными характеристиками служат генераторы.

Высокая температура (тысячи и десятки тысяч градусов) в источниках света приводит к распаду молекул большинства веществ на атомы. Поэтому эмиссионные методы служат, как правило, для атомного анализа и только очень редко для молекулярного.

Излучение источника света складывается из излучения атомов всех элементов, присутствующих в пробе. Для анализа необходимо выделить излучение каждого элемента. Это осуществляют с помощью оптических приборов — спектральных аппаратов, в которых световые лучи с разными длинами волн отделяются в пространстве друг от друга. Излучение источника света, разложенное по длинам волн, называется спектром.

Спектральные аппараты устроены таким образом, что световые колебания каждой длины волны, попадающие в прибор, образуют одну линию. Сколько различных волн присутствовало в излучении источника света, столько линий получается в спектральном аппарате.

Свет, разложенный в спектральном аппарате в спектр, можно рассматривать визуально или зарегистрировать с помощью фотографии или фотоэлектрических приборов. Спектральные аппараты — монохроматоры — позволяют выделять свет одной длины волны, после чего он может быть зарегистрирован с помощью фотоэлемента или другого электрического приемника света.

При качественном анализе необходимо определить, к излучению какого элемента относится та или иная линия в спектре анализируемой пробы. Для этого нужно найти длину волны линии по ее положению в спектре, а затем с помощью таблиц определить ее принадлежность тому или иному элементу. Для рассмотрения увеличенного изображения спектра на фотографической пластинке и определения длины волны служат измерительные микроскопы, спектропроекторы и другие вспомогательные приборы.

- хезмәттәшлектә башкаларның фикерләрен исәптә тоту һәм карашыңны яклый белү;
- бердәм эшчәнлектә уртак нәтиҗәгә килү.

**Шәхси:**

- Ярдәмчеллек, башка кешеләргә карата кайгыртучан булу.

**Предметара бәйләнеш**: география, математика, сәнгать, Россия тарихы, җәмгыять белеме, экономика

**Дәрес тибы:** катнаш, практик эш элементлары белән дәрес-дискуссия

**Җиһазлау:** компьютер, проектор, индивидуаль карточкалар

**Төп төшенчәләр:**болгар, илтабар, әмир, кәрван-сарай

**Дәреснең эпиграфы:**

-Сез кайдан?- дип сорыйсыз,
-Без Казаннан, Иделдән.
Идел-эчкән су булыр.

**Дәрес барышы**

I.**Оештыру өлеше**

II. **Актуальләшетерү**

***1. Дәрес темасын ачыклау***

- Ни өчен Бөек Болгар дәүләте кыска гомерле була һәм тарих агымына сизелерлек йогынты ясый алмый? *(Дәүләт тиешенчә ныгып өлгерми. Кубрат хан үлгәннән соң, уллары хакимият өчен көрәшә башлыйлар һәм җирләрне үзара бүлешәләр)*

- Дәүләт нинди өлешләргә таркала? *(Кубратның Аспарух исемле улы халыкның бер өлешен Дунай ярларына алып китә. Болгарларның күпчелеге Кубратның икенче улы белән берлектә үзләренең төп җирләрендә торып кала. Калган болгарлар үзләренең яңа ватаннарын табалар.Идел һәм Кама арасындагы җирләр аларның туган җиренә әверелә.)*

- Ә кайсы өлеше безнең борынгы бабаларыбызның ватаны була? *(Идел буе болгар дәүләте)*

- Димәк, без бүген **Идел буе Болгар дәүләте** турында өйрәнәбез.

***2. Дәрес максатын билгеләү****(укучылар дәреснең максатын һәм бурычларын куялар)*

***3. Дәрес планы белән танышу:***

1. Болгар дәүләтенең территориясе һәм халкы
2. Идел Болгарстанында идарә
3. Болгарларның хуҗалык эшчәнлеге
4. Сәүдә мөнәсәбәтләре
5. Дин
6. Идел болгары-шәһәрләр иле

**III. Төп өлеш**

***1.Болгар дәүләтенең территориясе һәм халкы***

-Укучылар, сезгә Идел буе болгар дәүләте турында мәгълүмат язылган карточкалар таратылган. Әлеге мәгълүмат белән танышабыз һәм сорауларга җавап бирәбез.

- IX-XI гасырларда дәүләт нинди территорияләрне биләгән?
- XI-XIII гасырлада Идел буе Болгар дәүләте территориясе киңәя, картадан аның чикләрен күрсәтегез.
- Х гасырда дәүләт белән ничә хан идарә итә?*(10)*
- Илнең халкын төрле кабиләләр тәшкил иткән. Болгарлар белән беррәттән тагын нинди кабиләләр яшәгән?*(суарлар, барсиллар, бәрәнҗәрләр, биләрләр, искилләр)*
- Каратадан әлеге кабиләләр белән бәйле булган шәһәрләрне табыгыз.

***Микронәтиҗә:*** *Татарстан территориясендә беренче дәүләт IX гасыр ахыры-X гасыр башында барлыкка килә.Ул Идел буе Болгар дәүләте дип атала. XI-XIII гасырлар әлеге дәүләтнең көчле һәм чәчәк аткан чоры була. Болгарлар белән беррәттән дәүләттән суарлар, барсиллар, бәрәнҗәрләр, биләрләр, искилләр дә яшәгән.*

***2. Идел болгарстанында идарә***

-Ә хәзер дәреслек материалын укып, түбәндәге сорауларга җавап бирәбез.

- Идел Болгарстанында кем идарә иткән? *(Илтабар, әмир)*
- Анда нинди идарә формасы була?*(Монархия)*
- Илнең беренче әмире кем булган? *(Алмыш)*
- Идарәче чикләнмәгән идарәгә ия булган дип раслап буламы?
- Дәүләт казнасы нәрсә хисабына тулыланган?

***Микронәтиҗә:*** *Идел буе Болгарстаны феодаль дәүләт була. Югары хакимият илтабар яки әмир кулында. Аның шәхси дружинасы була. Дәүләт казнасы бай була, ул халыктан- салым, сәүдәгәрләрдән пошлина җыю хисабына тулылана.*

***3.Болгарларның хуҗалык эшчәнлеге***

- Гарәп географы Ибне Рөстәнең “болгарлар – игенче халык” дигән сүзләре сезгә дәреслек буенча таныш инде. Россия тарихчысы С.М.Соловьев “болгарлар сәүдәле һәм сәнәгатьле халык” дип язган. Кем хаклы? Ә хәзер, ике төркемгә бүленеп, бер төркем Ибне Рөстә, икенче төркем С.М.Соловьев фикерен дәлилли. Дәлилләрне таблица формасында дәфтәргә язабыз.
- Ә хәзер чыганак белән танышабыз һәм болгарларның хуҗалык тормышын характерлый торган сүзләрне язып алабыз.

***922 елда Болгар илендә булып киткән Багдад хәлифәте илчелеге секретаре Ибн Фадлан көндәлегеннән***

Үзебез бара торган сакалиблар (болгар) патшасы янына барып җитәргә бер көн һәм бер төн ара юл калгач, ул, безне каршы алу өчен, үз кул астындагы 4 патшаны, агай-энеләрен һәм улларын җибәрде. Алар безне икмәк, ит, тары белән каршы алдылар һәм безгә иярделәр. Аңарга кадәр ике фәрсах юл калгач, ул безне каршы алды, безне күргәч, атыннан төште һәм йөзтүбән капланды... Аның кулында дирхәмнәр иде, һәм ул аларны безнең өскә сипте. Ул безнең өчен тирмәләр куйды. Һәм без шул тирмәләргә урнаштык.

***Микронәтиҗә:1 төркем.*** *Болгарлар игенчелек белән шөгыльләнгәннәр. Бодай, тары, арпа, ясмык һ.б. культуралар үстергәннәр. Авыр сабан, җиңел сука, урак кебек эш*

*кораллары кулланганнар. Шулай ук терлекчелек белән шөгыльләнгәннәр. Ат, сыер, кәҗә, сарык асраганнар.*

***2 төркем.*** *Болгарларда кәсепчелек нык үскән. Алар аучылык (сунарчылык), балыкчылык, бал җыю кәсебе белән шөгыльләнгәннәр. Шулай ук һөнәрчелек алга киткән. Борынгы бабаларыбыз металлургия, тире иләү, чүлмәк ясау, эрләү һәм туку, зәркан сәнгате кебек һөнәрләрне үз иткән. Болгарларда төзелеш сәнгате бик камил булган. Алар таштан һәм кирпичтән сарайлар, мәчетләр, кальга каланчалары, җәмәгать мунчалары, торак йортлар төзегәннәр.*

***4. Физкультминутка***

***5. Сәүдә мөнәсәбәтләре***

- Болгарларның географик урыны сәүдә белән шөгыльләнү өчен уңай булганмы?*(Әйе, чөнки алар Идел һәм Кама буйларында урнашканнар.)*

- Әйе, илнең географик яктан уңайлы урнашуы сәүдә үсешенә этәргеч биргән. Идел һәм Кама су юлы Көнчыгыш Европада иң зур сәүдә юлы булган. Болгар җирендә бик күп кәрван юллары кисешкән. Аларның берсе-Киевка, икенчесе- Хәрәземгә, өченчесе Итилгә илткән. Зур шәһәрләрдә чит ил хакимнәре сәүдә эшен хуплаганнар, чөнки сәүдә казнага гаять зур табыш китергән: читтән керә торган товарлар бәясенең уннан бер өлеше дәүләт файдасына калдырылган. Ә хәзер тагын болгарлар турындагы чыганакка мөрәҗәгать итәбез һәм аларның нинда илләр белән сәүдә итүен ачыклыйбыз. Нинди товарларны читкә чыгарган, ә нindiләрен керкән?

***Микронәтиҗә:*** *10 гасырда ук инде Идел Болгарстаны эре сәүдә үзәгенә әверелә. Аның төп сәүдә төбәге булган Ага-Базарда ел саен ярминкәләр үткәрелеп килгән. Ул Кытай, Һиндстан, Иран, Көнчыгыш Гарәп илләре, Русь, Византия, Балтыйк буе, Скандинавия илләре белән сәүдә иткән. Чит ил сәүдәгәрләре белән сәүдә иткәндә болгарлар дирһәм белән түләгәннәр, ә үзара тире белән исәпләшкәннәр. Алар экспортка мехлар, хайван тиреләре, кораллар, терлекләр, йомшак күн, балавыз һәм бал, агач материаллар чыгарганнар, читтән алтын һәм көмеш тәнкәләр, Димәшкъ корычы, ефәк, парча, келәмнәр, исле майлар һәм аш тәмләткечләр, савыт-саба, бизәнү әйберләре керткәннәр.*

***6. Дин***

***Картина өстендә эш***

- Бу картинада нинди вакыйга сурәтләнгән? *(Ибн Фадланның Идел буена килүе)*
- Кем ул Ибн Фадлан *(10 нчы гасырда яшәүче гарәп сәяхәтчесе һәм язучысы)*
- Ул нинди максат белән Идел буена килә?*(Ислам динен тарату өчен)*

***Дәреслек белән эш***

- Ислам динен кабул иткәнче болгарлар нинди диндә булалар? *(мәҗүсилек)*
- Рәсми рәештә ислам дине кайчан кабул ителә? *(922 елда)*
- Кем идарә иткәндә Багдад хәлифәсенә ислам тәртипләре урнаштыруда ярдәм итү өчен илчелек җибәрүен үтенеп мөрәҗәгать ителә? *(Алмыш хан)*

***Вакыт сызыгында эш***

- Вакыт сызыгында болгарлар ислам дине кабул иткән елны күрсәтегез.
- Моннан ничә ел элек болгарлар ислам динен кабул иткәннәр? *(Моннан 1096 ел элек)*
- Руслар христиан динен болгарлар ислам динен кабул иткәннән соң ничә ел үткәч кабул иткәннәр?*(66 ел)*
- Татарлар ислам динен кабул итүнең 1100 елын кайчан бәйрәм итәрләр? *(2022 нче елда)*

***Төркемнәрдә эш***

***1 төркем. Ислам динен кабул итү сәбәпләрен ачыклый.***

***2 төркем. Ислам динен кабул итүнең нәтиҗәләрен ачыклый.***

***Микронәтиҗә:****922 нче елның июнь уртасында рәсми рәвештә ислам дине кабул ителә. Ислам дине кабул ителү нәтиҗәсендә Идел Болгары үзәкләштерелгән дәүләт буларак оешып җитә һәм ныгый, Болгар әмире-мөстәкыйль идарәчегә, ә Болгар иле бәйсез*

*дәүләткә әверелә, болгар халкы югары дәрәҗәдәге Көнчыгыш мәдәнияте белән аралашу мөмкинлеге ала, болгарларның көнкүреше үзгәрә: яңа гореф-гадәтләр, традицияләр барлыкка килә.*

***7. Идел болгары-шәһәрләр иле***

Дәреслектәге материал буенча таблица тутырырга

| **Болгар** | **Мәйданы** | **Халкы** | **Нинди һөнәр белән шөгыльләнгәннәр** |
|---|---|---|---|
| Кашан | 100 га | 8-10 мең | сугыш кораллары, көнкүреш кирәк-яраклары, алгын-көмештән бизәнү әйберләре ясау |
| Җүкәтау | мәгълүм түгел | мәгълүм түгел | металл кою, чүлмәкчелек, игенчелек, балыкчылык |
| Кирмәнчек | мәгълүм түгел | мәгълүм түгел | рус князьлекләре алып барган сәүдәдә алмаш сәүдә үзәге булып хезмәт иткән |
| Тубылгытау | 2 га | 10 мең | тимерчелек белән шөгыльләнгәннәр |
| Ашлы | 77 га | 50 | балыкчылык, чолынчылык, керамика |
| Суар | 100 га | 10 мең | тимерчелек, терлекчелек, игенчелек белән шөгыльләнгәннәр, көмеш акчалар да сукканнар |
| Болгар | 350-400 мең м$^2$ | 10 мең | тимерчелек, чүлмәкчелек, пыяладан бизәнү әйберләре ясау, сөяктән кирәк-яраклар ясау,төзүчелек, тире һәм мех эшкәртү, күн җитештерү |
| Биләр | 600 га | 70-100 мең | тимерчелек, чүлмәкчелек, пыяладан бизәнү әйберләре ясау, сөяктән кирәк-яраклар ясау, төзүчелек, тире һәм мех эшкәртү, күн җитештерү белән шөгылләнгәннәр |

5. **Рефлексия**
1. Идел буе Болгарстаны темасына кластер төзергә
2. Таблица тутырырга

| Плюс | Минус | Кызыклы |
|---|---|---|
| Дәрестә укучыга файдалы булган эш формалары, уңай эмоцияләр языла | Дәрестә укучыга ялыктыргыч тоелган, кирәк булмаган һәм аңлаешсызмәгълумат языла | Дәрестә булган кызыклы һәм тагын да күбрәк беләсе килгән фактлар, шулай ук укытучыга сораулар языла |

**Өй эше**

1. § 3 укырга, 25 нче биттәге сорауларга җавап
2. Microsoft Office Publisher программасында “Идел буе Болгар дәүләте”буклетын ясарга.
3. Интернет материалларын файдаланып, “Изге Болгарга экскурсия” дигән темага презентация төзергә

# ҖЫЙНАК ҺӘМ ҖӘЕНКЕ ҖӨМЛӘЛӘР

*Бәшәрова Язилә Зиннур кызы,*
*«Ядегәр авылы урта гомуми белем бирү мәктәбе»,*
*Кукмарарайоны*

**Максат:**

- укучыларны җыйнак һәм җәенке җөмләләр белән таныштыру, җыйнак җөмләләрне иярчен кисәкләр өстәп җәенкеләндерү һәм җәенке җөмләләрдән җыйнак җөмләләр ясау күнекмәләрен формалаштыру;

- әйтү максаты ягыннан җөмлә төрләрен камилләштерү, җөмләнең баш һәм иярчен кисәкләре турындагы белемнәрне системалаштыру, каллиграфик дөрес язу күнекмәләрен үстерү, сөйләм телен баету;

- язгы табигатькә сакчыл караш тәрбияләү.

Көтелгән нәтиҗәләр

Танып-белү УУГ(предметные УУД):

- әйтү максаты ягыннан җөмлә төрләрен аеру, җөмлә ахырында тиешле тыныш билгесен кую;

- җыйнак һәм җәенке җөмләләрне тану, аеру;

-җыйнак җөмләләрдән җәенке җөмлә һәм җәенке җөмләләрдән җыйнак җөмлә ясый белү;

Шәхси УУГ(личностные УУД):

- шәфкатьлелек, мәрхәмәтлелек, әхлаклылык сыйфатларын үстерү;

- туган телгә кызыксыну булдыру;

- иптәшеңнең эшенә, фикеренә карата хөрмәт булдыру;

Предметара УУГ(метапредметные УУД):

<u>Көйләгеч (регулятив) УУГ</u>:

- укучылар белгән, әлегәчә белмәгән күнекмәләрне үзара бәйләү;

- биремне үтәүнең дөреслеген тикшерү;

- үз эшенә контроль ясый һәм бәя бирә белү;

- укытучы ярдәме белән уку проблемасын табу һәм формалаштыру;

- төркемдә һәм парларда эшли белү;

<u>Танып белү (познавательные) УУГ:</u>

- җөмләләрне чагыштыра, охшаш һәм аермалы якларын билгели белү;

- фикерләүнең логик чылбырын төзи белү;

- укытучының сорауларына җавап бирә, тиешле мәгълүматны таба белү;

- уку барышында анализ (таркату) һәм синтез (берләштерү) гамәлләрен башкара белү;

<u>Коммуникатив УУГ:</u>

- укытучының, сыйныфташларның сорауларына җавап бирү;

- сөйләм этикеты нормаларын үтәү: исәнләшә, саубуллаша, рәхмәт белдерә белү;

- башкаларның сөйләмен тыңлый һәм аңлый белү;

- укыту процессында катнашу, иптәшеңнең үз-үзен тотышы белән идарә итү;

- үз фикерләрен әйтә белү;

Предметара бәйләнеш: әдәби уку, әйләнә-тирә дөнья, рус теле

**Дәреснең технологик картасы**

**I. Ориентлашу- мотивлаштыру**

**1.Уңай психологик халәт тудыру**

- Исәнмесез, укучылар! Кәефләрегез ничек?

- Шәп!

- Әйдәгез, бер-берегезгә карап елмаегыз да, кара-каршы дусларыбызны сәламлик әле. (куллар белән сәламләү). Хәзер янәшә дусларыбызны сәламлик. (бер-берсенең җилкәләрен тидерү). Хәзер тыныч кына утырабыз.

- Күзләрегезне йомып, мин булдырам дип кабатлыйбыз!

- Мин сезгә яхшы кәеф, дәрестә актив булуыгызны һәм яхшы билгеләр алуыгызны телим.

**2. Белемнәрне актуальләштерү**

- Без үткән дәрестә әйтү максаты ягыннан җөмлә төрләре белән таныштык, ә бүген мин сездән аларны аера, белүегезне һәм тыныш билгесен дөрес куюыгызны көтеп калам. Укучылар, почмакларга карагыз әле, анда җөмлә төрләре язылган. Һәрберегездә җөмләләр язылган карточкалар бар, шуларны карап чыгыгыз. Әйтү максаты ягыннан җөмләнең төрен билгеләгез. Ә хәзер торып басабыз, үзебезгә тиешле почмакны сайлыйбыз.

Җөмләләр (карточкада укучыларга таратыла)

Язгы каникулда ничек ял иттең

Син яз фасылын яратасыңмы (сорау җөмлә)

Кара каргалар, сыерчыклар кайттылар

Урамда гөрләвекләр ага

Тиздән язгы ташулар башланыр (хикәя җөмлә)

Их, ямьле дә соң язгы табигать

Бүген көн нинди матур (тойгылы җөмлә)

Әйдәгез, табигатьне саклыйк

Кошларга оялар ясыйк (боерык җөмлә)

- Дөрес басканлыгыгызны тикшерү өчен слайдка карыйбыз. Парлашабыз,

шушы җөмлә төре турында фикер алышабыз. (Һәр почмактагы укучыларның фикерен тыңлау).

Безнең барлык җөмләләр дә яз темасына караган. Яз көне бөтен табигать уяна, яшәрә. Агачларны сындырмаска, кошларны каршы алырга әзерләнергә, аларга оялар куярга кирәк. Табигатьне һәр кеше дә сакларга бурычлы.

- Рәхмәт! Урыннарга утырыгыз. Дәресебезне дәвам итәбез. Җөмләнең баш кисәкләрен искә төшереп үтик. Әйдәгез өстәлләрегездән "Җөмләнең баш кисәкләре" дигән тестны алабыз һәм биремнәрне үтибез.

1. Ия

а) мөстәкыйль мәгънәле һәм төрле килештәге исемнәр белән белдерелә.

б) җөмләнең баш килештә килеп, башка сүзгә буйсынмаган кисәге.

2. Иянең сораулары

а) кем? нәрсә?

б) кемнең? кемгә?кемдә?

в) кем? кемне? кемнән?

3. Җылы сөяк сындырмый, салкын җанны тындырмый.- бу җөмләдә ия:

а) сөяк

б) җанны

в) җылы, салкын

4. Хәбәр

а) ия турында нәрсә дә булса хәбәр итә һәм аңа буйсынып килгән кисәк

б) исем белән белдерелгән кисәкне ачыклап килүче сүз

5. Хәбәрнең сораулары

а) нишли? нишләде? нишләгән?

б) кем? нәрсә?

в) нишли? нинди?

Эшләребезне каршы иптәш белән алыштырабыз, карандашларны алып слайдтан карап тикшерәбез һәм бәялибез.

5 балл – хатасыз эш;

4 балл – 1 хата бар;

3 балл – 2 хата бар;

2 балл – 3 хата;

Иптәшегезгә эшен тапшырасыз. Үзбәя картасында тиешле баллны куябыз.

**3. Уку мәсьәләсе кую.**

- Дәфтәрләрне ачабыз һәм язабыз.

Унҗиденче апрель

Сыйныф эше

Җыйнак һәм җәенке җөмләләр

*Матур язу күнегүе*

Зәңгәрләнә күкләр.

Гөрләвекләр ага.

Карлы кыеклардан

Ак тамчылар тама. (Гамил Афзал)

- Хәзер әйдәгез, һәр җөмләнең иясен һәм хәбәрен табыйк та асларына сызыйк. Уйлап эшлибез! (Укучылар эшли, аннан соң укып тикшерелә)

1) Зәңгәрләнәкүкләр. (слайдта чыга)

2) Гөрләвекләрага. (слайдта чыга)

3) Карлы кыеклардан ак тамчылартама. (слайдта чыга)

- Рәхмәт. Искә төшерәбез: ия белән хәбәр җөмләнең нинди кисәкләре дип атала? (Җөмләнең баш кисәкләре). Рус телендә ничек атыйбыз? (Главные члены)

- Ә кайсы җөмләдә, нинди сүзләргә сызмыйча калдырдык? (3нче җөмләдә *Карлы, кыеклардан, ак* сүзләренә). Бу сүзләрнең астына нинди сызык сызабыз, кем әйтә ала? (укучылар фикере)

- Әйе, *кыеклардан* сүзенең астына пунктир (сызык-сызык) сызабыз (слайдта). Бу безнең тәмамлык. Ә *карлы, ак* сүзләренә дулкынлы сызык сызабыз. Болары аергыч була, сез аларны алдагы дәресләрдә өйрәнерсез әле.

- Бу сүзләр җөмләнең нинди кисәкләре дип атала? (Иярчен кисәкләре). Рус телендә без аларны ничек атыйбыз? (второстепенные члены)

- Кайсы җөмлә тулырак, камилрәк? (укучылар фикере)

- 1нче җөмләгә игътибар итәбез, нинди үзенчәлеге бар?

-(Бу җөмлә ия белән хәбәрдән генә тора)

- Монда тагын шундый җөмлә очрадымы? (Әйе, 2нче җөмлә). Икенче җөмлә дә – ия белән хәбәрдән генә тора.

- Хәзер 3нче җөмләгә карыйк. Ул җөмлә алдагы икесеннән нәрсә белән аерылды? (Иярчен кисәкләре булуы белән).

Җөмлә баш кисәкләрдән тыш иярчен кисәкләрнең булу-булмавына карап 2 төрле була.Җыйнак җөмләләр, җәенке җөмләләр.

Бүгенге дәресебезнең темасы да җыйнак һәм җәенке җөмләләр. Билгеләмәне дәреслектән карап үтик. Дәреслекнең 63нче битен ачабыз һәм билгеләмәне укыйбыз.

(Укучылар эчтән укыйлар).

- Нинди җөмлә җыйнак җөмлә була?

(Баш кисәкләрдән генә төзелгән җөмлә җыйнак җөмлә була.)

Мисаллар уйлыйк әле. (Укучылар мисаллары)

- Нинди җөмлә җәенке җөмлә була?

( Бер яки берничә иярчен кисәге булган җөмлә җәенке җөмлә дип атала)

Мисаллар уйлыйк.

Рус телендә без әлеге җөмлә төрләре белән очраштыкмы? Нинди җөмләләр дип атадык без аларны?

(Нераспространенные и распространенные предложения)

**II. Уку мәсьәләсен адымлап (өлешләп) чишү**

**1.Уку мәсьәләсен чишү**

- Дәреслекләрнең 63нче битен ачабыз, 88нче күнегүне эшлибез. (Укучылар мөстәкыйль эшлиләр, беткәч чылбыр буенча укып тикшерелә.)

Нәтиҗә ясау:

- Сез нинди җөмләләр яздыгыз? (Җыйнак җөмләләр). Үзбәя картасында эшебезне бәялибез, тиешле баллны үзебезгә куябыз.

5 балл - әгәр язуыгыз чиста, хатасыз булса;

4 балл - 1-2 хәреф хатасы бар;

3 балл - ия белән хәбәрне тапканда хата китсә;

2 балл - 1-2 хәреф хатасы, ия белән хәбәрне тапканда хата китсә;

МИКС-ФРИЗ-ГРУП – укучылар музыка астында бииләр. Музыка туктагач сорауга җавап булырлык итеп төркемгә берләшәләр.

- Әйтү максатыннан чыгып җөмләләр ничә төркемгә бүленде?

- Җөмләнең баш кисәкләре ничә? (2)

- Тамчы тама тып та тып. Бу җөмләдә ничә ия бар? (1)

**2. Белемнәрне ныгыту**

-Хәзер слайдка карыйбыз. Анда бирелгән сүзләрдән җөмләләр төзибез, тиешле тыныш билгеләрен куябыз. Уйлыйбыз, фикерлибез дәфтәрләрдә эшлибез!

1)сагынып, яз , килде , көткән

2) йөгерде, гөрләвекләр

3) куйдым, вазага, тал, мин, ботаклары

4) бөреләр, тиздән, күренер, нәни

5) нинди, яз, ямьле

- Язып бетердекме? Афәрин! Хәзер группаларда чиратлап җөмләләрне укыйбыз, калганнар иптәшләре аның белән килешәме, җөмләне дөрес төзегәнме уйлыйбыз.

-Үзбәя картасында эшебезне бәялибез, тиешле баллны үзебезгә куябыз.

5 балл - әгәр язуыгыз чиста, хатасыз булса;

4 балл - 1-2 хәреф хатасы булса,

3 балл - бер җөмләне дөрес төземәгән булсагыз;

2 балл – 2 җөмләне дөрес төземәгән булсагыз;

**3. Яңа белемнәрне үзләштерүне беренчел тикшерү.**

Хәзер әлеге язган җөмләләр буенча түбәндәге эшләрне башкарабыз. Уйла, фикер йөрт, җавабыңны дәфтәреңә яз! (слайдта)

1. Җыйнак җөмләнең номерын яз.

2. 1нче җөмләдән җыйнак җөмлә ясап яз.

3. Ничәнче җөмләнең иясе алмашлык белән белдерелгән? Җөмләнең номерын һәм алмашлыкны яз.

4. Биредә тойгылы җөмлә бармы? Булса номерын яз.

5. Җыйнак җөмләдән җәенке җөмлә ясап яз.

- Дәфтәребезне уң яктагы янәшә иптәшебезгә бирәбез. Слайд буенча иптәшебезнең эшен тикшерәбез. (Эшләребезне тикшерәбез)

1. 22. Яз килде.3. 3, мин4. 5

5. Гөрләвекләр ашыгып йөгерде. (Нәни гөрләвекләр йөгерде. Җитез гөрләвекләр йөгерде.)

Иптәшебезнең эшен бәялибез. Хәзер

үзбәя картасында тиешле баллны куябыз.

5 балл – хатасыз эш;4 балл – 1 хата бар;3 балл – 2 хата бар;2 балл – 3 хата

4. Белемнәрне ныгыту

- Эшебезне дәвам итәбез. Слайдта бирелгән җыйнак җөмләләргә иярчен кисәкләр өстәп җәенке җөмләләр итеп язабыз.

(слайдта)

1. Яз җитте.2. Көннәр җылынды.3. Кара каргалар кайтты.4. Сыерчыклар килде.

5. Кошлар оя ясыйлар.

- Тәмамладыгызмы? Бик яхшы, кем үзенең җөмләләрен укырга тели? (2-3 укучы тыңланыла)

**III. Рефлексия, бәяләү**

**1. Өй эше**бирү

Хәзер дәресебезгә йомгак ясыйк.

- Укучылар,  сез бүген үзегезгә нинди яңалыклар алдыгыз?

- Минем сезнең дәресне ничек аңлавыгызны беләсем килә. Бер уен уйнап алабыз.

Мин әйткән белән килешсәгез басасыз. Килешмәсәгез урыннарда утырган килеш каласыз.

- Иярчен кисәкләре булган җөмлә – җыйнак җөмлә.

- Җөмлә ия белән хәбәрдән генә тора ала.

- Кояш елмая. – Бу җыйнак җөмлә.

- Җыйнак җөмләдән җәенке җөмлә ясап була.

**3.  Дәрескә гомуми бәя кую.**

- Хәзер үзбәя картасын алабыз балларыбызны кушып язабыз, үзебезгә тиешле билгене куябыз.Бәяләү нормасы:

17-20 балл булса “5”ле,  14-16 балл булса “4”ле,  11-13 балл булса “3”ле,

10 баллдан әзрәк булса “2”ле билгесе куела.

- Сезнең өстәлләрегездә смайликлар бар. Дәрес турында фикерләрегезне смайликлар ярдәмендә күрсәтеп , ишек төбендәге тукталышка беркетегез.

  - Мин дәресне аңладым. Иптәшемә аңлата алам.

 - Мин дәресне аңлап бетермәдем.

- Мин дәресне аңламадым.

- Дәрес өчен рәхмәт! Булдырдыгыз! Сау бул

## ФОЛЬКЛОРНЫЕ ЖЕМЧУЖИНЫ

*Васильева Надежда Леонидовна,*
*учитель русского языка и литературы*
*МБОУ “Яныльская средняя школа”*
*Кукморского муниципального района РТ*

Значение русского народного творчества огромно. В последние годы повсеместно началось приобщение к народным истокам, возрождение старинных обычаев и обрядов. Нельзя прерывать связь времен и поколений, чтобы не исчезла, не растворилась в неотразимой Вселенной душа русского народа, так же, как встарь, должны наши дети быть участниками традиционных на Руси праздников, именуемых святками, петь песни, водить хороводы, играть в любимые народом игры.  Детский фольклор – обширная область устного народного творчества. Это целый мир – яркий, радостный, наполненный жизненной силой и красотой. Он способствует рядом с миром взрослых. Дети с живым интересом вглядываются в жизнь взрослых и охотно заимствуют их быт.        Мысль детей связана с конкретными образами – в этом ключ к тайнам детского художественного творчества.        Сближение с русской народной культурой необходима современной молодежи. Дети становятся добрее и внимательнее друг к другу, расширяется их кругозор, и повышается интерес к познанию окружающего мира через игру, песни, импровизации. У детей развивается воображение, эстетические вкусы, творческая фантазия. Детская игра является первым проявлением театрального чувства. Работу кружка буду организовывать с учётом опыта детей и их возрастных особенностей.

Предлагаемая программа имеет художественно-эстетическую направленность, которая является важным направлением в развитии и воспитании. Программа предполагает развитие у детей художественного вкуса и творческих способностей.

Программа кружка «Русские фольклорные жемчужины» составлена на 3 года обучения для обучающихся 12-14 лет. Занятия проводятся 3 раза в неделю по 2 часа. Практические занятия составляют большую часть программы.

***Цель программы:***

- пробудить у обучающихся живой интерес к изучению русского детского фольклора.
- привить интерес к изучению истории, традиции, обычаев русского народа

***Задачи программы:***

***Образовательная:***

- *дать общее представление о содержании и объёме понятия «детский фольклор», о его классификации, основных жанрах, их функциях, генезисе и художественном своеобразии.*

***Развивающая:***

- *развивать кругозор, интерес к народному слову, его истории.*

***Воспитательная:***

- *воспитывать чувство национальной гордостиза свой народ, его культурное наследие, воспитывать внимательное отношение к слову, культуру речи.*

В результате занятий в кружке «Русские фольклорные жемчужины» учащиеся

**должны знать:**

- о фольклоре как источнике народной мудрости;
- пройденный фольклорный материал;
-основные русские календарные праздники и уметь рассказывать о них, особенности традиционных календарных праздников;
- основные жанры фольклора.

**должны уметь:**

- выразительно читать фольклорное или литературное произведение, учитывая его жанровое своеобразие;
- видеть логику сюжета и обнаруживать в ней идею произведения;
- видеть отражение мифологических представлений древних славян в фольклорных и литературных произведениях;
- выявлять художественную роль символов и изобразительно-выразительных средств в фольклорном и литературном тексте;
- сочинять небольшие произведения фольклорного жанра (загадки, мифы, сказки)
- рассказать о каком либо обряде, обычаю; - участвовать в конкурсах знатоков народных традиций; - участвовать в разыгрывании обрядов; - записать обряд (со слов информанта, из книг, из беседы учителя и т.п.) Реализовать цели и задачи помогут различные ***формы и методы***:

- лекции,
- творческие задания,
- практические работы,
- самостоятельный поиск,
- выразительное чтение и др.

Формы и методы должны быть такими, чтобы они давали возможность обучающимся самостоятельно искать пути решения возникающих проблем, повышать интерес к предмету, развивать культуру общения.

***Принципы,****лежащие в основе программы:*

- доступности (простота, соответствие возрастным и индивидуальным особенностям);
- наглядности (иллюстративность, наличие дидактических материалов). “Чем более органов наших чувств принимает участие в восприятии какого-нибудь впечатления или группы впечатлений, тем прочнее ложатся эти впечатления в нашу механическую, нервную память, вернее сохраняются ею и легче, потом вспоминаются” (К.Д. Ушинский);
- демократичности и гуманизма (взаимодействие педагога и ученика в социуме, реализация собственных творческих потребностей);

- научности (обоснованность, наличие методологической базы и теоретической основы).

Тематика занятий строится с учетом интересов учащихся, возможности их самовыражения. В ходе усвоения детьми содержания программы учитывается темп развития специальных умений и навыков, уровень самостоятельности, умение работать в коллективе.

***Планируемый результат:***

-выразительное чтение и анализ произведений народной словесности;
-инсценирование фольклорных произведений;
-написание творческих работ;
- более высокий уровень знаний, умений, навыков;
- участие в различных творческих конкурсах;
- составление альбома лучших работ;
- защита проектов;
- творческий отчет руководителя кружка на педсовете;
- проведение мастер-классов.

**Учебно-тематический план 1 года обучения**

| **№** | **Разделы** | **Теория** | **Практика** | **Всего** |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Введение в курс. | 2 | | 2 |
| 2 | Приметы времен года. | 16 | 20 | 36 |
| 3 | Мир фольклора – мир народной мудрости. | 10 | 24 | 34 |
| 4 | Песенное народное творчество. | 12 | 26 | 38 |
| 5 | Всему свое время. | 10 | 24 | 34 |
| | **Итого:** | **50** | **94** | **144** |

**Содержание**

**Введение (2 ч.)**

Вводное занятие. Знакомство с предметом. Цели и задачи кружка.

**Приметы времен года (36ч.)**

Тема: **«Сентябрь – румянец осени».** Приметы сентября. Песенки – игры. Загадки.

Считалки. Пословицы и поговорки. «Паучок», «Кисанька-мурысанька», «У медведя во бору».

Тема: **«Октябрь – листопад, грязник, подзимник».** Приметы октября. Загадки.

Считалки. Пословицы и поговорки. Скороговорки. Игровой хоровод. Перевёртыши. Плясовые песни. «Сидит Дрема», «Посмотрите, как у нас-то в мастерской», «Обруч круж».

Тема: **«Декабрь – вершина года».** Приметы декабря. Пословицы и поговорки. Загадки. Колыбельные. Считалки, скороговорки. Песня – игра. Плясовые песни. Колядки. Зимние поздравительные обходы. «Ой, морозушка-мороз!», «Ах, ты, котинька-коток», «Веники», «Авсень!».

Тема: **«Январь – снеговик, трескун, году – начало, зиме - серёдка».** Приметы января. Пословицы и поговорки. Считалки. Зимняя сказка. Загадки. Песня – игра. «Батюшка мороз», «Чем тебя, Ванюшка, батюшка дарил?»

Тема: **«Февраль – лютый, снежень, кривые дороги».** Приметы февраля.

Пословицы и поговорки. Считалки. Масленица. Масленичные песни. Загадки. Игры. «Зимний вечер», «А мы Масленицу дожидаем», «Едет Масленица», «Катаются, катаются», «Прощай, масленица-плутовка!».

Тема: **«Март–протальник, предвесенье».** Приметы марта. Загадки.

Пословицы и поговорки. Весенние заклички. Скороговорки. Песни – игры. «Ой кулики», «Грачи-киричи», «Динь-бом», «Море, берег».

Тема: **«Апрель – снегогон, водолей, первоцвет».** Приметы апреля. Пословицы и поговорки. Весенние заклички. Считалки. Молчанки. Весенние поздравительные обходы. Докучные сказка. Песни – игры. «Весна красна!», «Гори, гори ярче!», «Далалынь», «Трынцы-бранцы», «Вокруг коршуна хожу».

Тема: **«Май – травень, цветень».** Приметы мая. Пословицы и поговорки.

Величальные песни. Загадки. Считалки. Заклички. Песни – игры. Масленица. Масленичные песни. Игры. «Аленький наш цветок», «Гори, гори ясно», «В синем море-океане».

**Мир фольклора – мир народной мудрости (34 ч.)**

Тема: **«Мир фольклора – мир народной мудрости»**. Осенние песни – заклички.

Повторение любимых песен, игр, считалок, загадок.

Тема: **«Осень – перемен восемь».** Встреча осени. Осенние приметы. Песни.

Игры. Сказки. Докучные сказки. Пословицы и поговорки. Загадки. Считалки. Скороговорки. Осень золотая. Спасы. Успение. Покров. «Осень, осень, в гости просим!», «Серпы золотые», «Курочка-рябушечка», «Мышка, мышка!», «Кто больше вспомнит», «Где был Иванушка?», «Теремок».

Тема: **«Здравствуй, гостья зима».** Предзимье и его приметы. Зимние заклички.

Загадки. Считалки. Пословицы и поговорки. Песни. Игры. Хороводы. Колыбельные. Подготовка к зимним святкам. Колядки. Зимушка - зима. Новый год. Рождество. Святки. Крещение. «По-загороду гуляет Царевич-королевич!», «Кто у нас хороший», «Земляничка-ягодка», «А баю, баю», «Сидит олень», «Репка», «Авсень!»

Тема: **«Не пугай, зима, весна придёт!»** Зимние приметы. Святочные игры.

Песни. Зимние забавы и заклички. Загадки. Считалки. Пословицы и поговорки. Масленица. Масленичные песни. Предвесенье. Весенние заклички. Игры. «Коляда!», «Как у бабушки козел», «Зайчик ты, зайчик!», «Ванюшка мой!», «Наша Масленица годовая!», «Ты прощай, прощай, наша Масленица!», «Ай, кулик, клик!», «Эй, ребята, не робейте!», «Дома ли, кума, воробей?», «Идет Матушка-Весна!»

Тема: **«Весна – красна нам добра принесла!»** Приметы весны. Хороводы.

Трудовые песни. Песни – игры. Загадки. Считалки. Пословицы и поговорки. Скороговорки. Докучные сказки. Перевёртыши. Весна - веснянка. Масленица. Великий пост. Вербное воскресенье. Пасха. «Весна красна», «Бояре», «Кострома, Кострома!», «Мак маковистый», «Ой ты, зоренька-заря», «Земелюшка-чернозем».

**Песенное народное творчество (38 ч.)**

Тема: **«Где песня льётся, там легче живётся»**. Встреча осени. Осенние приметы.

Песни осенних трудовых обрядов. Народные инструменты. Свадебные игры с куклами. Игровые хороводы. Плясовые песни. Пословицы и поговорки. Загадки. Скороговорки. «Жнем, жнем!», «Сидит дед на меже», «Про житного деда», «Шла утица по бережку», «Ходит сон по горе», «Спи-ка, Сашенька, усни!», «Баю-баюшки», «Вот и шел я по дороге», «Вот они!», «Селезня я любила», «Вью, вью, вью я капусточку», «Сидит Дрема», «Ой досточка, досточка Ельмовая».

Тема: **«Беседа дорогу коротает, а песня - работу».** Приметы поздней осени.

Осенние посиделки. Песни. Игры. Загадки. Пословицы и поговорки. Скороговорки. Народные инструменты. «Мы девицы», «Ты река ли, моя реченька», «Селезень утицу гонял».

Тема: **«Были бы песни - будут и пляски».** Зимние приметы. Песни – игры.

Народные инструменты. Загадки. Шутки – прибаутки и небылицы. Скороговорки. Подготовка к Зимним Святкам. «Было у матушки двенадцать дочерей», «Тушки-тутушки», «Во горнице», «Пошла Коляда!»

Тема: **«Куда запевала, туда и подголоски»**. Зимние приметы. Зимние Святки.

Колядки. Песни. Игры. Загадки. Шутки – прибаутки. Небылицы. Скороговорки. Народные инструменты. Пословицы и поговорки. «Уж как шла Коляда!», «Из-за леса, из-за гор», «Со вьюном я хожу», «Летал, летал воробей», «Прялица», «Посидите, гости, побеседуйте», «А Масленая недалечко», «Блины».

Тема: **«Добро того учит, кто слушает»**. Приметы предвесенья. Весенние

заклички. Игры. Пословицы и поговорки. Загадки. Скороговорки. Народные инструменты. «Жаворонушки», «Весну пора звать», «Весна-Весеница!», «На горе-горе петухи поют», «Тетерка шла».

Тема: **«Всё в свой прок»**. Народная мудрость о весне, о труде. Пословицы и

поговорки. Заклички. Хороводные игры. Традиционные праздники летнего календаря и их песни. «Ой весна, ты весна!», «Уж вы, девицы!», «Ой, Махоня!», «У нашей у Дуни!», «У на по кругу, по широкому», «Во поле березонька стояла», «Юрий!».

**Народная мифология (34 ч.)**

Тема: «**Родина краше солнца».** Пословицы, поговорки, песни. «Ты живи, Россия, здравствуй!»

Тема: **«Всему своё время»**. Время и ритмы в народных песнях и танцах.

Календарные, хороводные, плясовые колыбельные песни. Пословицы и поговорки. Скороговорки. Приметы народного календаря. «На горе пышаница», «Мы вечор торгу торговали», «Паучок», «Кострома», «Не долго веночику…», «Покупайся, утушка», «Мимо саду».

Тема: **«Песня поётся не как придётся, а надо лад знать».** Характерные интонации песен различных регионов России: Урала, Сибири, Севера, Центрального, Поволжья. Пословицы и поговорки. Приметы народного календаря. «Золотые ворота», «Ой да закипучий да ключ», «Пошла млада за водой», «Медведюшки йдут», «А дидили дидили», «Я качу, качу», «Ох, Авсень!», «Как летела пава», «Сею, вею, повеваю».

Тема: **«Какова песня, таковы и слова»**. Песни святочных гаданий.

Хороводные, игровые, свадебные, колыбельные, лирические песни. Пословицы и поговорки. Приметы народного календаря. «А дай Бог», «Колядки», «Лели-лели», «Возле саду, саду», «У нас по саду река текла», «Величальная», «Небылица», «Во затейной слободе», «Ходит царь», «Масленица-кривошейка!», «Маслинка», «Масленица-гологузка», «Ой мы Масленицу прокатали», «Жавороночки», «Солнышко-ведрышко», «Уж ты, пташечка», «Веснянка», «Вербочка», «Прячу, прячу реешок».

Тема: **«Какова погудка - такова и пляска».** Инструментальные наигрыши и

пляски. Хороводные, плясовые и строевые песни. Пословицы и поговорки. Приметы народного календаря. «Весна красна!», «А мы просо сеяли», «Во горнице», «То не гусельки», «Дождик, дождик пуще!», «Мы-то молодчики», «Жила я у пана», «Как задумал мещанин», «Гори, гори жарко», «Ох и слава Богу!».

**Учебно-тематический план 2 года обучения**

| № | Разделы | Теория | Практика | Всего |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Введение в курс. | 2 | | 2 |
| 2. | Жанры устного народного творчества. | 4 | 12 | 16 |
| 3. | Загадки. | 4 | 20 | 24 |
| 4. | Русские народные песни. | 2 | 8 | 10 |
| 5. | Потешный фольклор. | 6 | 24 | 20 |
| 6. | Русские народные игры. | 4 | 20 | 24 |
| 7. | Русские народные сказки. | 2 | 16 | 18 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 8. | Обрядовая поэзия. | 2 | 12 | 14 |
| 9. | Старинный русский быт. | 2 | 18 | 20 |
| 10. | Поэзия пестования. | 2 | 16 | 18 |
| 11. | Бытовой фольклор. Потешный фольклор. | 4 | 20 | 24 |
| 12. | Игровой фольклор. Фольклорные посиделки. | 2 | 24 | 26 |
| | **Итого:** | **56** | **160** | **216** |

**Содержание**

**Введение в курс (2 ч.)**

Вводное занятие. Знакомство с предметом. Цели и задачи кружка.

**Жанры устного народного творчества (16 ч.)**

Пословицы, поговорки. Классификация. Тематическое содержание. Тверские пословицы поговорки. Скороговорки, чистоговорки.Сочинение чистоговорок.

**Загадки (24 ч.)**

Вводное занятие.Тематическое содержание. Классификация загадок. Фонетический и лексический анализ загадок. Типы загадок (вопрос, описание, сравнение, шарады, метаграммы, анаграммы, логографы, загадки-трафаретки). Тверские загадки. Сочинение загадки. Викторина загадок. Лотерея загадок.

**Русские народные песни (10 ч.)**

Тематика песен. Колыбельные песни. Песни тверского народа. Заклички, приговорки. Победа в воздухе не вьется, а руками достается Войны – защитники Отечества. Слушание патриотических песен.

**Потешный фольклор (20 ч.)**

Вводное занятие. Голосянки. Молчанки. Скороговорки. Сечки. Небылицы. Небылицы-перевёртыши.

**Русские народные игры (24 ч.)**

Организационное занятие. Жеребьёвки. Считалки. Считалки – числовки. Заумные считалки. Сочинение считалочки. Игры драматизированные. Игры хороводные. Игры с диалогами. Игры – ловишки. Словесные игры-фанты. Словесная игра «Путаница». Березовая карусель Русские народные подвижные игры.

**Русские народные сказки (18 ч.)**

Присказки. Признаки сказок. Тематика сказок. Сказки о животных. Бытовые сказки. Волшебные сказки. Былины. Сочинение сказок.

**Обрядовая поэзия (14 ч.)**

Зимние святки. Масленица. Весна. Закликание весны. Пасха. Лето. Троица.

**Старинный русский быт (20 ч.)**

Одежда. Традиционный костюм. Обувь крестьян и бояр.

Семейные праздники. Игры и забавы детей. Семейные обряды. Именины.

**Поэзия пестования (18 ч.)**

Колыбельные песни. Пестушки. Потешки. Прибаутки. Докучные сказки.

**Бытовой фольклор. Потешный фольклор (24 ч.)**

Детские народные песни. Заклички и приговорки. Детская обрядовая песня. Прозвища и дразнилки. Детские сказки. Страшилки. Словесные игры. Молчанки и голосянки. Поддёвки. Сечки. Скороговорки. Небылицы-перевёртыши. Загадки. Шутку шутить – людей насмешить. Народный юмор (докучные сказки, скороговорки, дразнилки).

**Игровой фольклор. Фольклорные посиделки (26 ч.)**

Формальные ролевые игры без поэтически организованного текста. Формальные ролевые игры с игровыми припевами. Формальные ролевые игры с приговорками. Игры - импровизации. Жеребьёвые сговорки. Считалки. Подготовка к «Фольклорным посиделкам».

**Учебно-тематический план 3 года обучения**

| № | Разделы | Теория | Практика | Всего |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Введение в курс. | 2 | | 2 |
| 2. | Мир глазами древних людей. | 4 | 20 | 24 |
| 3. | Человек как часть космоса. | 2 | 20 | 22 |
| 4. | Пространство. Время. | 2 | 16 | 18 |
| 5. | Символика числа и цвета в славянской мифологии и фольклоре. | 2 | 14 | 16 |
| 6. | Человек: символика тела. Человек: цикл жизни. Жизненный круг. Семья. | 2 | 16 | 18 |
| 7. | Семейно-бытовые обряды и обрядовый фольклор. | 4 | 22 | 26 |
| 8. | Календарные обряды и поэзия. Календарно-обрядовый фольклор. | 6 | 12 | 18 |
| | **Итого:** | **24** | **120** | **144** |

**Содержание**

**Вводное занятие. Знакомство с предметом. Цели и задачи кружка (2 ч.)**

**Мир глазами древних людей (24 ч.)**

Процесс познания мира древними людьми. Мифологическое мышление. Миф как способ осмысления мира. Обрядовые действия.

Кодирование информации с помощью особых знаков-символов. Пространственные, временные, растительные, животные, абстрактные символы. Символическая картина мира (пространство: верх-низ; небо-земля; правый-левый; время: день-ночь; лето-зима; социальное устройство общества: мужской - женский; старший - младший; свой - чужой).

Представление о мировом дереве, связывающем три мира - Правь, Явь, Навь.

Отражение мифологических представлений об устройстве мира в фольклоре (загадки, пословицы, волшебные сказки).

**Человек как часть космоса (22 ч.)**

**Тотемические верования** древних славян и их отражение в народных сказках о животных. Представление о магической силе женщины, связующей мир природы и человеческое общество. Особое отношение древних людей к мертвым.

**Взаимоотношения человека и природных стихий.** Двойственное отношение древнего человека к природе.

**Вода** – самая могущественная из стихий, первооснова жизни, ее начало. Ритуальные очищения с помощью воды. Очищение водой в свадебном и погребальных обрядах.

Переправа через реку в фольклорных произведениях - символ препятствия, границы, перехода из старой жизни в новую.

**Земля -** олицетворение плодородия, мать всему живому, кормилица.

**Огонь**. Символическая функция огня - уничтожение-очищение. Очаг - особое место в жилье.

Современные ритуалы, связанные с огнем (поклонение Вечному огню, зажигание Олимпийского огня).

**Воздух** - промежуточное пространство между населенными небом и землей. Способность перемещаться по воздуху - свойство волшебное. Ветер - могущественная, враждебная человеку стихия, символ вольной - волюшки.

**Духи природы** (леший, водяной, русалка).

Профессии, связанные со стихиями. Сверхъестественные свойства, приписываемые в фольклоре мельнику, кузнецу, пасечнику, гончару.

**Пространство. Время (18 ч.)**

Пространство свое (положительное, немагичное) и чужое (отрицательное, таинственное, связанное с миром мертвых). Правое и левое. Граница и центр.

Пространство дома. Дом - центр мира, соединяющий небо, землю и подземный мир. Символическое значение углов, порога, дверей, окон. Печь-центр дома. Домовой.

Отражение представлений древних славян о пространстве дома в фольклоре (*загадки, поговорки, пословицы, приметы, заговоры).*

Линейное и циклическое время. Календарный год.

Солнце, месяц, день и ночь. Солнце и месяц - противоположные начала. День – свое время, ночь - чужое. Движение по солнцу – правильное, обратное неправильное. Животные - символы дня и ночи.

**Символика числа и цвета в славянской мифологии и фольклоре (16 ч.)**

Символическое значение красного, черного и белого, зеленого, золотого цветов.

Выразительное чтение и комментирование обрядовых песен, небылиц, загадок, фрагментов былины «Мамаево побоище», сказки «Купеческий сын Иван».

Число как символ. Четные и нечетные числа. Символическое значение чисел 1,2,3,4, 7,9,12.

**Человек: символика тела. Человек: цикл жизни. Жизненный круг. Семья (18 ч.)**

Тело как космос (положительный верх, отрицательный низ, центр - середина; правое и левое, переднее и заднее). Магическая сила тела. Символическое значение органов и частей тела. Защита тела. Обереги.

Ритм жизни в семье. Особое место каждого члена семьи в зависимости от пола и возраста. Семейные отношения и традиции

**Семейно-бытовые обряды и обрядовый фольклор (26 ч.)**

Отражение в фольклоре представлений народа о важнейших моментах человеческой жизни: рождении, вступлении в брак, смерти.

**Родильные и крестильные обряды.** Родильные и крестильные обрядовые песни.

**Свадебные обряды**: сватовство, смотрины, сговор, рукобитье. Девичник-мальчишник, расплетание косы, утро свадебного дня, сборы свадебного поезда, приезд жениха, стол в доме невесты, молодые в доме жениха, княжий стол, послесвадебные обряды. Свадебные песни: символика, художественные особенности (синтаксический и психологический параллелизмы, повторы, постоянные эпитеты и др.) Величальные и корильные песни.

**Похоронные обряды и поэзия.** Мотив посмертных превращений, перевоплощений душ умерших в птиц, деревья, растения. Мотив извечного круговорота: жизнь-смерть - жизнь. Отражение представлений о мировом дереве.

**Календарные обряды и поэзия. Календарно-обрядовый фольклор (18 ч.)**

Ритуальные, заклинательные, величальные, корильные песни.

**Зимние обряды.** Колядки. Пожелание благополучия, счастья, богатства.

Масленица. Масленичные песни и обряды.

**Весенне-летние обряды.** Заклинание весны. Веснянки.

Обряд завивания березки. Ритуальные игры.

Семицкие и Троицкие обряды и песни. Купальские и жнивные обряды и песни.

Творческий отчёт в конце года. Выставка готовых работ. Чему мы научились за год.

Методическое обеспечение образовательной программы

*Педагогическое сопровождение программы:*

Формы и методы работы: беседы, викторины, конкурсы, экскурсии, наблюдения, рассказы, составление эссе, сбор материалов (фотографии, газетных материалов), работа с источниками Интернет – сайтов, составление карт – схем, встреча с интересными людьми, практикуется посещение краеведческих музеев: п. Кукмор.

*Дидактический материал:* книги, брошюры, газетные материалы, сведения из Интернета, особенности русской народной культуры, её похожесть и различия с фольклором других народов, русские народные праздники: бытовые и религиозные, народные игры:

календарные, обрядовые, событийные, детские, развивающие, картографические материалы о Кукморском районе (об истории села, о природных особенностях родного края, о населении).

*Методическое обеспечение программы:*

- система тестов по вопросам, русского фольклора, истории родного края
- викторины и творческие задания по основным темам
- памятки по проведению анкетирования, интервью.

*Список использованной литературы*


1. Аникин В.П. Русский фольклор. – М., 1985г.
2. Аникин В.П. Русское народное поэтическое творчество.-Л.,1987г.
3. Журавлёв В.П. Звук и смысл. – М., 1991г.
4. Кравцов Н.И, Лазутин С.Г. Русское устное народное творчество.- М., 1989г.
5. Мартынова А.Н. Потешки, считалки, небылицы.- М., 1989г.
6. Мельников М.Н. «Русский детский фольклор»: учебное пособие для студентов пед. ин-тов – М: Просвещение, 1987г.
7. Орлова Л.Г. Использование элементов фольклора на уроках русского языка.- СПб., 1995г.
8. Русские народные загадки, пословицы, поговорки /Составитель, автор вступительной статьи Круглов Ю.Г.- М., 1990г.
9. Русские народные сказки./Составитель Афанасьев А.Н.- М., 2011г.
10. Снегирев И.М. «Русские простонародные праздники и суеверные обряды»- М.,1980г.
11. Степных В.А. Использование пословиц, поговорок в учебном процессе // Н.Ш.1988г., №5.
12. Ушинский А.Д. Родное слово // Собрание сочинений – М., Л., 1999г.

Энциклопедический словарь юного литературоведа / Составитель Новиков В.И. – М., 2008г.


## КУШМА ҖӨМЛӘ
## (БиС технологиясенең “Алгоритм” картасына нигезләнеп үткәрелгән дәрес конспекты)


*Валиева Гөлсинур Шәмсемөхәммәт кызы,*
*МБГБУ “Масловка урта гомуми белем мәктәбе”,*
*Балык Бистәсе муниципаль районы.*


Предмет:татар теле (9 нчы сыйныф)

Тема :Кушма җөмлә

Үткәрү формасы : БиС технологиясенең “ Алгоритм” картасы буенча.

Ресурслар: ОСУД (Схема), карточкалар, эш дәфтәрләре, компьютер, проектор, презентация,дәреслек :Р.З.Хәйдәрова ,Р.Л.Малафеева. Татар теле: Рус телендә урта гомуми белем бирүче мәктәбенең 9 нчы сыйныфы өчен дәреслек ( рус телендә сөйләшүче балалар өчен) Казан, “Мәгариф” нәшрияты.

Кулланылган әдәбият: 1. Качество в образовании.Технология БиС.Технологическая карта «Алгоритм». Обучающий фильм на русском языке.

2. Интернет ресурслар:http://knigabis.kz/; https://www.youtube.com/user/VassermanF

***Максат:*** Дәрестә уку материалының укучылар тарафыннан үзләштерелү дәрәҗәсен норматив таләпләрдән чыгып 63% җиткерү . Укучыларның эшләү тизлеген, логик һәм критик фикер йөртүләрен, мәгълүмати компетентлыгын, сүз байлыкларын үстерү. Фәнне сыйфатлы үзләштерүгә кызыксыну уяту.

***Бурыч :*** Технологик карта регламентын үтәү.

***Планлаштырылган нәтиҗә:*** Куелган максатка ирешү.

***Дәреснең 1 нче төре.*** Яңа теманы өйрәнү һәм беренчел ныгыту буенча оештырылган дәрес түбәндәге өлешләрдән тора: мотиавация ------ актуальләштерү ----- яңа теманы кабул итүгә әзерлек ------ яңа тема үзләштерү ----- теманы үзләштерү дәрәҗәсен беренчел тикшерү ------ ныгыту --- анализ ---- рефлексия.

Укытучы дәрес башлаганчы тактага МПМ (таблицаны тактада бирү- бирмәү укытучы ирегендә) дәреснең темасын, яңа теманың үзләштерелү дәрәҗәсенең нормативын( 63%), технологик картаның исемен, В 1 , В 2, В3 ( теманы аңлату өчен сарыф ителгән вакытны билгеләү өчен), дәрес этапларын чагылдырган таблицаны һ .б язмаларны куя.

**Дәреснең технологик картасы**

1. Оештыру өлеше. Мотивация.

- Хәерле көн, укучылар. Исәнмесез. Укучылар, кәефләрегез ничек? Сез дәрескә әзерме? Бүгенге татар теле дәресебезнең темасы *“Кушма җөмлә*. Без бүген БиС технологиясенә нигезләнеп төзелгән “Алгоритм” картасы буенча эшләячәкбез. Бу карта буенча эшләүнең үз таләпләре бар. Шул таләпләрнең иң мөһиме: бүгенге яңа теманың сезнең тарафтан үзләштерелү нәтиҗәсен 63% җиткерү. Ягъни, дәрес азагында арагыздан (4 укучының) өчегез “4”ле һәм “5”ле алсагыз, нәтиҗәбез яхшы, таләп ителгән норма үтәлгән дип санала ала. Мин сезгә уңышлар телим, барыгыз да “5” ләр генә алыр дип ышанам. Хәзер сүзне лидерыбызга бирәбез.

Лидер:

- Сөйләмебез матур булсын,
Кушма җөмләләр кулланыйк.
Теманы тырышып өйрәнеп,
Төпле белемнәр алыйк! **(Кул чабалар).**

**Дәфтәрләргә число һәм теманы язалар.**

-Укучылар, яңа теманы өйрәнә башлаганчы без сезнең белән, бу теманы үзләштерү өчен кирәкле булган материалны искә төшерергә тиешбез.Татар теле һәм әдәбият дәресләрендә без сүзлек өстендә эшлибез, яңа өйрәнгән сүзләрнең тәрҗемәләрен яттан өйрәнәбез. Бу безгә ни өчен кирәк? *(Татарча сөйләшә, аралаша белү өчен)*

- Аерым сүзләрне генә белү, ятлау аралашу өчен җитәрлекме? Без бер- беребез белән нәрсәләр ярдәмендә аралашабыз? *(Җөмләләр).*

-Узган уку елында,8 нче сыйныфта, без нинди җөмләләрне өйрәндек? *(гади җөмләләрне)*

- Укучылар, ә нинди җөмләләрне без гади җөмләләр дип атыйбыз? *(Җаваплар русча булырга мөмкин, бергәләп тәрҗемә ителәләр: которые состоят из одной грамматической основы- 1 подлежащее и одно сказуемое, или только 1 подлежащее, или только 1 сказуемое)*

- Ә ике иясе, ике хәбәре булган җөмлә буламы? Бу очракта нинди җөмләләр турында сүз бара? *(Кушма җөмләләр)*

**Слайд.** Гади җөмлә, кушма җөмлә. Мондый төр җөмләләр дә рус телендә дә, татар телендә дә бар.

**Слайд.** - Ике яки икедән артык гади җөмләдән торган җөмлә кушма җөмлә дип атала. А как же связываются эти простые предложения в составе сложного. Для этого в нашем языке существуют союзы. Союзы в татарском языке имеют такие же функции, как и в русском. Их классификация также совпадает в обоих языках.

**Слайд .**Союзы бывают сочинительные (тезүче теркәгечләр): һәм (и); ләкин (но); яки (или) и подчинительные (ияртүче теркәгечләр): чөнки (потому что); әгәр (если), шуңа күрә, и др.*( Дәфтәрләрендә язып куела : Тезүче теркәгечләр, Ияртүче теркәгечләр)*

- Теркәгечләр ике төрле, дидек. Алар кушма җөмлә эчендәге ике гади җөмләне бәйлиләр. Шуннан чыгып кушма җөмләләрнең без ике төрен карарбыз: Тезмә кушма җөмлә һәм Иярченле кушма җөмлә.Тезмә кушма җөмлә булганда, гади җөмләләр берсе артыннан берсе тезелеп киләләр, иярченле җөмлә булса, бер җөмлә икенчесен ияртеп килә.

**Слайд. Кагыйдә.**Гади җөмләләре үзара тезү юлы белән бәйләнгән җөмләләрдән торган җөмлә тезмә кушма җөмлә дип атала.(Сложносочиннными называются предложения, в которых простые связываются друг с другом сочинительными союзами или интонацией.)

Гади җөмләләре үзара ияртү юлы белән бәйләнгән җөмләләрдән торган җөмлә иярченле кушма җөмлә дип атала.(В сложноподчиннном предложении придаточное предложение подчиняется главному при помощи различных средств, а в нашем случаи, при помощи подчинительных союзов). *(Дәфтәрләрендә язып куела: Тезмә кушма җөмлә, Иярченле кушма җөмлә)*

- Укучылар, без сезнең белән яңа теманы үзләштерү өчен кирәкле кагыйдәләрне искә төшердек. Бу белемнәр сезгә алдагы дәресләрдә “ Тренажёр” картасы буенча эшләгәндә дә зур ярдәм булыр дип ышанам.

- Хәзер дәресебезнең “Сынау” ( проба) циклына күчәбез. Әйдәгез, схемаларны (**ОСУД**-*обобщенная система учебных действий*) кулларыбызга алыйк. Яңа теманы үзләштерү барышында сез түбән, уртача, югары катлаулылыктагы биремнәрне үтәргә тиеш буласыз. Хәзер сез нинди алгоритм(схема) белән һәм ничек эшләргә тиеш икәнне карыйбыз.

**Слайд *Һәр укучы алдында һәм слайдта ОСУД ( теманы үзләштерү өчен кирәкле схемалар) лар. Укытучы теманы ОСУД ның һәрбер өлеше буенча аңлата. Укучылар белән аралашу булырга тиеш. Вакытны (В 1) (аңлату башланган вакыт) тактада билгели.***

- Ә хәзер тактада язылган җөмләләрне карагыз. Җөмләләрне укыйбыз, сезнең белән бергәләп тәрҗемә итәбез, схемалар ярдәмендә төрләрен билгелибез.

**Слайд.** Туган ягыбызга алтын көз килде. Агачлардан җиргә сары, яшел, кызыл яфраклар коела. Көннәр әле җылы, ләкин бик еш яңгырлар ява. Ай башында көннәр салкын булды, шуңа күрә төннәрен хәтта кырау төште. Тиздән көчле салкыннар килер һәм кар ява башлар. *(Һәрбер җөмлә аерым укыла, схема буенча карала, нәтиҗә ясала бара, төрләре билгеләнә)*

- **Сүзлек.** *Кырау төште – здесь: былизаморозки.*

- Укучылар, кайсыгыз җөмлә төрен ничек билгеләргә кирәклеген аңламады? Андыйлар юк.***Вакытны (В 1)(аңлату беткән вакыт) тактада билгели.*****(Карточкалар таратыла).**

- Укучылар, хәзер без сезнең белән өч төрле катлаулылыктагы биремнәрнең өчесен дә эшләрбез. Беренче түбән катлаулылыктагы (ТКБ) биремдә җөмләне күчереп язарга, баш кисәкләренең асларына сызарга һәм җәяләр эчендә гадиме, кушмамы икәнен күрсәтергә кирәк.

**Слайд.** ( Безнең татар халкы китапка һәрвакыт хөрмәт белән караган.)

Икенче – уртача катлаулылыктагы (УКБ) биремдә җөмләләрне укырга, тәрҗемә итәргә, гадиме кушмамы икәнен билгеләргә һәм кушма җөмләләрне генә күчереп язарга, ия һәм хәбәрнең астына сызарга кирәк.

**Слайд.** ( Һәр өйдә китап иң кадерле урында сакланган. 1906 елның 2 нче гыйнварында Казанда беренче татар китапханәсе ачыла. Китапханә “Болгар” кунакханәсендә урнаша һәм ул “Шәрыкъ кунакханәсе “ дип атала.)

Югары катлаулылыктагы (ЮКБ) биремнәрдә кушма җөмләләрнең төрләрен (Тезмә кушма җөмләме, иярченле кушма җөмләме икәнен ) билгеләргә кирәк булыр. **Слайд.** (Татар телендә беренче китап гарәп хәрефләре белән языла, һәм ул 1612 нче елда Лейпциг шәһәрендә басыла. X гасырда татарлар гарәп графикасын куллана башлыйлар, чөнки бу вакытта Болгар дәүләте ислам динен кабул итә.)

- Кем нәрсә эшләргә кирәклеген аңламады?

**1нче цикл.**

(Һәрцикл "Укучыларның субъектив тәҗрибәләрен актуальләштерү","Яңа теманы кабул итүне оештыру", "Теманы аңлауны оештыру", "Рефлексия" өлешләреннән тора)

- Дәфтәрләргә **"Сынау"** дип язабыз. Каләмнәрне куябыз. Бергәләп 1 тапкыр кул чабалар **(ХЛОПОК)** һәм эшли башлыйлар. **3 + 30**

( Рәт арасында йөреп тикшерә. Эшләп бетергән укучылар кулларын күтәрәләр. 3 укучыдан соң вакытны билгеләп 30 секунд көтә.)

- Дәфтәрләрне алмашабыз. Каләмнәрне куйдык. Кулда каләм - хата. Тикшерәбез. **Слайд *(дөрес җаваплар)*** *(Һәр бирем аерым тикшерелә).*

- Укучылар, дөрес җавапларны слайдта күрәсез. Күршегезнең җавабы дөрес булса, кулыгызны күтәрәсез. (Укытучы саный – башта ТКБ биремнәрен һәм тактада билгели ТКБ > яки <, аннары УКБтикшерелә һәм тактада билгеләнә, (**Слайд**) һәм ЮКБ биремнәрен(шул ук тәртиптә)(**Слайд**)билгели).

- Укучылар, кем игътибарсызлык аркасында хата ясады ? ( Кул күтәрәләр, саный, таблицада билгели).

- Кемгә вакыт җитмәде? ( Кул күтәрәләр, саный, таблицада билгели).

- Кем теманы аңлап бетермәү аркасында ялгышты? ( Кул күтәрәләр, саный, таблицада билгели һәм нәтиҗә ясый):

***1 нче нәтиҗә.*** Димәк, без нәрсәне аңлап бетермәдек соң? ***Аңлата башлый һәм В2 гә вакытны яза.*** (Мәсәлән, аңлату, якынча шушы формада булырга мөмкин.): Эш барышында шуны билгели алдык: әле кайберләрегез җөмләнең грамматик нигезен дөрес билгели алмый. (*Таблицада тема астына "Грамматик нигез" дип яза).* Бу җөмләнең төрен дөрес билгеләргә комачаулый, вакытыгыз күп китә. Шулай ук теркәгечләр темасын да начар беләбез. *(аска яза).* Тәрҗемә итү дә җиңел түгел, чөнки текстлар һәм җөмләләр фәнни стильгә карый. *(Тема астында сүзлек, тәрҗемә кебек язулар барлыкка килергә мөмкин).*

- Тагын бер кат искә төшерик әле. Җөмләнең грамматик нигезен билгеләүне без иядән башлыйбыз. Җөмләдә нәрсә турында сүз бара- шул ия була . Ия баш килештәге исем белән белдерелә. Ия турында җөмләдә нәрсә хәбәр ителә – шул хәбәр була. Тагын бер кат ОСУД-схеманы алыгыз әле. Теркәгечләрне табабыз. Тезүче теркәгечләр(сочинительные союзы): һәм (и); ләкин (но); яки (или); Ияртүче теркәгечләр (подчинительные ): чөнки (потому что); әгәр (если), шуңа күрә һ.б.***Тактада вакыт В2 языла (аңлату беткәнне күрсәтүче)***

**2 нче цикл**

- Дәфтәрләргә **"Ныгыту"** дип язабыз. Каләмнәрне куйдык. Бу циклда УКБ һәм ЮКБ *( Вакытка карап 1 нче яки 2 нче җөмләне генә бирергә мөмкин)* өстендә эшлибез. Сез әзерме? Кулларны әзерләдек.**(Хлопок).** Башлыйбыз. **3+ 30 секунд.**

( Укытучы рәт арасында йөреп тикшерә. Эшләп бетергән укучылар кулларын күтәрәләр. 3 укучыдан соң вакытны билгеләп 30 секунд көтә.)

- Дәфтәрләрне алмашабыз. Каләмнәрне куйдык. Кулда каләм - хата. УКБ (ППС) ны тикшерәбез. **Слайд**

-Укучылар, дөрес җавапларны слайдта күрәсез. Күршегезнең җавабы дөрес булса, кулыгызны күтәрәсез. (Укытучы саный – башта ППС биремнәрен һәм тактада билгели ППС > яки <, аннары һәм ВПС биремнәрен **(Слайд** ВПС > яки <билгели).

- Укучылар, кем игътибарсызлык аркасында хата ясады ? ( Кул күтәрәләр, саный, билгели).

- Кемгә вакыт җитмәде? ( Кул күтәрәләр, саный, билгели).

- Кем теманы аңлап бетермәү аркасында ялгышты? ( Кул күтәрәләр, саный, билгели).

***2 нче нәтиҗә.*** Укытучы, күзәтүләреннән чыгып, нәтиҗә ясый.

- Кушма җөмләләрне билгеләгәндә, башта баш кисәкләрне дөрес таба алу мөһим, һ.б. ЮКБ дәге 2 нче җөмлә аша аңлатырга да мөмкин.

**3нче цикл**.

- Дәфтәрләргә **“ХӘТЕР”** дип язабыз. Каләмнәрне куйдык. Бу циклда УКБ һәм ЮКБ *(1әр җөмләне генә бирергә мөмкин)* өстендә эшлибез. Сез әзерме? Кулларны әзерләдек. **(кул чабу).** Башлыйбыз. **3+ 30 секунд.**

( Рәт арасында йөреп тикшерә. Эшләп бетергән укучылар кулларын күтәрәләр. 3 укучыдан соң вакытны билгеләп 30 секунд көтә.)

- Дәфтәрләрне алмашабыз. Каләмнәрне куйдык. Кулда каләм - хата. УКБ (ППС) ны тикшерәбез. **Слайд**

- Укучылар, дөрес җавапларны слайдта күрәсез. Күршегезнең җавабы дөрес булса,кулыгызны күтәрәсез. (Укытучы саный – башта ППС биремнәрен һәм тактада билгели ППС > яки <, аннары һәм ВПС биремнәрен **(Слайд)**ВПС > яки <билгели.

- Укучылар, кем игътибарсызлык аркасында хата ясады ? ( Кул күтәрәләр, саный, билгели).

- Кемгә вакыт җитмәде? ( Кул күтәрәләр, саный, билгели).

- Кем теманы аңлап бетермәү аркасында ялгышты? ( Кул күтәрәләр, саный, билгели).

**Рефлексия.** Дәрес материалының үзләштерү дәрәҗәсенә нәтиҗә ясала. Билгеләр куярга да, куймаска да мөмкин. Өй эше. Дәреслекнең 40 нчы битендәге 4 нче күнегү (ОСУД –схема буенча аңлатырга ).

## ЯХШЫЛЫК ЭШЛӘ – ҮЗЕҢӘ ДӘ ЯХШЫЛЫК БЕЛӘН КАЙТА

*Габбасова Гамилә Мәгъсүм кызы,*
*“Ядегәр авылы урта гомуми белем бирү мәктәбе”,*
*Кукмара районы*

**Предмет:** әдәбият

**Дәрес темасы: Ф. Яруллинның “Зәңгәр күлдә ай коена” һәм “Кояштагы тап” экиятләрен чагыштыру**

**Дәрес тибы:** яңа белем бирү

**Дәреснең максаты:**

1. Өйрәтү максаты: әдәбият теориясе буенча белемнәрне актуальләштерү; Ф. Ярулинның “ Зәңгәр күлдә ай коена”, “Кояштагы тап” әсәрләренә анализ ясау, чагыштыру; монологик һәм диалогик сөйләм телен үстерү.

2. Белем үстерү максаты: укучыларны үз фикерләрен дөрес, эзлекле әйтә белергә өйрәтү; әсәрдән иң мөһим фикерне аерып алу күнекмәләрен үстерү.

3. Тәрбияви: укучыларда әхлаклылык сыйфатлары тәрбияләү.

**Эш формалары:** индивидуаль, парларда, төркемнәрдә эш.

**Универсаль уку гамәлләре формалаштыру**.

**Шәхескә кагылышлы УУГ:** телне өйрәнүгә кызыксыну уяту, үзеңнең сөйләмеңне камилләштерергә омтылу.

**Регулятив УУГ**: укытучы ярдәмендә дәреснең максатын билгели һәм формалаштыра белү; үткәнгә карап бердәй бәяләү дәрәҗәсендә эш үтәлешенең дөреслеген бәяләү.

**Коммуникатив УУГ:** үзеңнең фикереңне телдән матур итеп әйтә белү, башкаларны ишетә һәм тыңлый белү.

**Танып-белү УУГ**: танып-белү максатын билгеләү, кирәкле мәгълүмат туплау; үткәндә өйрәнгәнне яңасыннан аера белү, дәреслектән, дәрестә алган мәгълүматтан файдаланып, сорауларга җавап бирү

**Планлаштырылган нәтиҗәләр**

**Предметлы**: укылган әсәрнең эчтәлеген үзләштерү, анализлый белү

**Шәхескә кагылышлы**: бәлагә юлыккан кешегә ярдәм итү; булган тискәре сыйфатларны бетерү өстендә эшләү; ярдәмчел, намуслы булу кебек сыйфатларны тәрбияләү

**Метапредметлы**: укытучы ярдәмендә дәреснең максатын билгели һәм формалаштыра белү; үткәнгә карап бердәй бәяләү дәрәҗәсендә эш үтәлешенең дөреслеген бәяләү.

Төп төшенчәләр: төп герой, ярдәмче образлар

Предметара бәйләнеш: рус әдәбияты, тарих, татар теле, география (астрономия)

Төп ресурслар: Әдәбият. 5 сыйныф: татар телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен уку әсбабы /Ф.Ә.Ганиева, Л.Г.Сабирова. Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2014. -175 бит.

Өстәмә ресурслар: мультимедиалы презентация, дәфтәр, тестлар, карточка, үзбәя таблицасы

**Дәрес барышы**

| Үткәрү технологиясе | Укытучы эшчәнлеге | Укучы эшчәнлеге |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| **I.Ориентлашу-мотивлаштыру этабы.( 5-10 минут)** | | |
| **1.*Уңай психологик халәт тудыру*** **Максат:** - укучыларны уку хезмәтенә хәзерләү; - балаларның игътибарларын туплау. | - Хәерле көн, укучылар! Кәефләрегез ничек? Әйдәгез әле, елмаеп, бер-беребезне сәламлик. Укучылар, әйдәгез, дәресебезне башлап җибәрик. Мин сезнең игътибарлы булуыгызны һәм дәрестә актив катнашуыгызны телим. | Бер-береңә уңай энергия бирү. |
| ***2. Актуальләшт*** | - Укучылар, без әдәбият дәресләрендә нинди темаларны өйрәндек? | - Ф.Яруллинның экиятләрен |

| | | |
|---|---|---|
| ***ерү***<br>**Максат:**<br>- яңа белемнәр формалаштыруга әзерләнү. | -Ә хәзер белемнәребезне тикшереп алыйк.<br>**(**1 нче эш)<br>Мин сезгә план өләшәм, сез андагы (“Зәңгәр күлдә ай коена” әкиятендә) вакыйгаларның барышы дөрес булырлык итеп төзегез. Төркемнәрдә эшлибез. Үзебезнең белемнәрне үзбәя картасында билгелибез.<br>Җаваплар слайдта чыга.<br>-Укучылар, әлеге җөмләләр кайсы әкияттән булды?<br>(2нче эш)<br>Индивидуаль биремле эш.<br>1.Малайга әнисе суны кайдан алып кайтырга куша?<br>1)ерактагы инештән<br>2)бакчадагы коедан<br>3) тау артындагы чишмәдән<br>2.Малай әнисенә ничек җавап бирә?<br>1) “Суны иртән тору белән алып кайтып куйсаң булмый идемени?”<br>2) “Тукта, мин бераз уйныйм әле”<br>3) “Хәзер, әнием, мин тиз генә алып кайтам”<br>3.Кояшның каралу сәбәбен әнисе ничек аңлата?<br>1) “Кемдер бу дөньяда изге гамәл кылган булырга тиеш”<br>2) “Кемдер бу дөньяда ялган эш кылган булырга тиеш”<br>3) “Кемдер бу дөньяда игелекле эш кылган булырга тиеш”<br>Укучылар, җавапларыгызны уң як күршегезгә бирегез. Җавапларны тикшерәбез.<br>3 дөрес җавап 3 балл, 2 дөрес җавап 2 балл, 1дөрес җавап 1 балл<br>-Укучылар, әлеге тест кайсы әкият буенча булды? | укыдык<br>- “Зәңгәр күлдә ай коена”, “Кояштагы тап” әкиятләре белән таныштык.<br><br>Укучылар җавапларны тикшерә.<br><br>-“Зәңгәр күлдә ай коена” әкиятеннән<br><br>Укучылар тестны эшлиләр.<br><br>Укучылар җавапларын күршеләренә бирәләр, алар бәяли һәм кире үзләренә кайтара.<br><br>-Тест “Кояштагы тап” әкияте буенча ясалган. |
| ***3.Уку мәсьәләсе (УМ) кую.***<br>**Максат:**<br>уку мәсьәләсен кую һәм | - Укучылар, ә хәзер бер риваять тыңлагыз.<br>Укытучы ана хикәятен сөйли.<br>- Уйлап карагыз әле, укучылар, мин нигә шушы хикәятне укыдым икән?<br>- Димәк, без сезнең белән нинди темага сөйләшәчәкбез? | - Укучылар игътибар белән тыңлый<br><br>-Яхшылык, яманлык |

<table>
<tr>
<td>адымлап чишүгә этәрү.</td>
<td>- Безнең максатыбыз нинди булыр дип уйлыйсыз?<br>- Чыннан да, яхшылык кылу иң матур сыйфатларның берсе икәнлеген исбатлап карарбыз.</td>
<td>-“Зәңгәр күлдә ай коена”, “Кояштагы тап” әкиятләрен чагыштыру; геройларны билгеләү;<br>Яхшылык белән яманлыкны аерырга өйрәнү</td>
</tr>
<tr>
<td>II. Уку мәсьәләсен адымлап (өлешләп) чишү этабы. (25 – 30 минут)</td>
<td>1.Мәкальләр “Кояштагы тап” әкиятенә туры киләме? Уңай җавапларны “+”, тискәре җавапларны “-” тамгасы белән билгеләгез. Тамгаларны мәкальләрнең алгы ягына куябыз.<br>Бирем төркемнәрдә эшләнә. Эш ике төркемгә төрле итеп бирелә.<br>1 нче төркемгә бирем.
<table>
<tr><th>Ж жава плар</th><th>Мәкальләр</th><th>Ж жава плар</th></tr>
<tr><td></td><td>Ата-ананы тыңлаган – адәм булган, тыңламаган – әрәм булган</td><td></td></tr>
<tr><td></td><td>Ата-анасын хурлаган үзен хурлаган булыр</td><td></td></tr>
<tr><td></td><td>Алтмышка җитсен бала,<br>Ана өчен һаман да бала.</td><td></td></tr>
<tr><td></td><td>Ата-анасына игелек күрсәтмәгән, олыгайгач, үзе дә игелек күрмәс</td><td></td></tr>
<tr><td></td><td>Ана күңеле балада, бала күңеле далада</td><td></td></tr>
<tr><td></td><td>Үз анасын зурлаган – кеше анасын хурламас</td><td></td></tr>
</table>
2 нче төркемгә бирем
<table>
<tr><th>Ж авап лар</th><th>Фикерләр</th><th>Ж авапл ар</th></tr>
<tr><td></td><td>Ай уңай образ</td><td></td></tr>
<tr><td></td><td>Чуртан һәм Гөберле бака дөрес эшли</td><td></td></tr>
<tr><td></td><td>Айсылу - ямьсез кыз</td><td></td></tr>
<tr><td></td><td>Ай Айсылуны матур кыз дип атый. Сез килешәсезме?</td><td></td></tr>
<tr><td></td><td>Үзеңнең гомереңне куркыныч астына куеп, башкаларга ярдәм кулы сузу дөресме?</td><td></td></tr>
<tr><td></td><td>Кешегә яхшылык эшләгән</td><td></td></tr>
</table>
</td>
<td>Укучылар төркемнәрдә сул яктагы буш урынга уңай җавапларны “+”, тискәре җавапларны “-” тамгасы белән билгелиләр.<br><br>Укучылар уңай җавапларны “+”, тискәре җавапларны “-” тамгасы белән билгелиләр дә карточкаларны читкә куялар.</td>
</tr>
</table>

| | | |
|---|---|---|
| | һәр кеше матур кешегә әверелә ала | |
| | **2 нче эш.**<br>1.Әсәргә анализ<br>-“Зәңгәр күлдә ай коена” экияте нәрсә турында?<br>-Әсәрдәге геройларны билгелик. Кайсы төп герой, кайсы ярдәмче герой? Ни өчен?<br><br>-Ә хәзер “Кояштагы тап” экиятенә күчик. Әкият нәрсә турында?<br><br>- Әсәрдәге геройларны билгелик. Төп герой, ярдәмче персонажларны табыйк.<br>- | - Яхшылык, яманлык турында<br>- Эчке матурлык, тышкы матурлык турында<br>- Ай – төп герой; гөберле бака, чуртан, Айсылу – ярдәмче персонажлар.<br>-“Кояштагы тап” экияте ялган, ялганның ачылуы, әниләргә карата булган мөнәсәбәт турында.<br>- Төп герой малай, ана |
| | - Укучылар, ә чынлыкта ай нинди соң?<br>Укытучы ай турында сөйли.<br>Ай – ул җирнең иярчене, планеталар арасында җиргә иң якын урнашкан иярчене. Яктылык буенча кояштан кала икенче, зурлыгы буенча бишенче урында тора. Җир белән айның арасы 384467 км. Ай кеше булган бердәнбер астрономи объект булып тора. Ай тышча, югары мантия, урта мантия, түбән мантия һәм төштән тора. Анда атмосфера юк диярлек.<br>(Интернет аша ай турында видеоязма күрсәтелә.<br>Адресы:http://yandex.ru/clck/jsredir?bu=uniq151861238177511777586&from=yandex.ru%3Bsearch%2F%3Bweb%3B%3B&text=&etext=1697.QPNKQAepIhT5xmQlIDKCmGjI7ZGyz9m2pIBKoFOa7yoVmLRA-Xqh6op7ZUgHPCtMz6K8DQvfJrTj-WK2ADAAzA.7fb27dff2933e652a0edabfab3f2786f38f90809&uuid=&state=Em5uB10Ym2xSIrus_UvOLJC9NBWY9mtMZYdb02A_vx2iL023znCjjBFQNfsleV5jw_v8XQwViC56ZWcTPTbdpA,,&&cst=AiuY0DBWFJ4CiF6OxvZkNH1SLehLetdzlfl8xTxp3kUDzNM021AN7Wmwu-ibcD_clJgZHCyAU-wwJl5yoUDJCUUmrp5PvBIp6ELZhMxZcuBuGu1L2E3Mk1cCH_upv2pcZDAVxj7VIhre7m9ppmlWWhOx6EASUUyG3iN3E ru.Wikipedia.org)<br>- Укучылар, әсәрдә әйтелгән ай белән чынбарлыктагы ай туры киләме?<br>- Укучылар, ә кояш турында ниләр беләсез? | Укучылар белгәннәрен әйтәләр.<br><br>Укучылар фикерләрен әйтәләр.<br><br>Бер укучы кояш системасы турында сөйли.<br>**Кояш**— Җир шарына иң якын йолдыз.<br>Кояш — Кояш системасының бер дәнбер йолдызы. Аның тирәсендә планеталар һәм аларның иярченнәре, кәрлә |

| | | |
|---|---|---|
| | Укытучы Кояш планетасының рәсемен күрсәтә. | планеталар һәм аларның иярченнәре, астероидлар, метео роидлар, кометала р һәм галәми тузан әйләнә. Кояш водородтан, гелийдән һәм башка кече концентрацияле элементлардан гыйбарәт. Кояшның орбиталь тизлеге 217 км/с тәшкил итә. Кояшның абсолют йолдызча зурлыгы + 4,83$^{m}$ тәшкил итә. |
| | - **Физкультминутка** | Парта кырыена басып, “шаян тычкан” белән бергәләп күнегүләр ясыйлар |
| | -Укучылар, текстлар буенча эшне дәвам итәбез һәм яңадан таблицаларыбызга әйләнеп кайтабыз. Таблицаның икенче ягына тамгаларны куеп чыгыгыз әле. Аермалар барлыкка килдеме?<br>Төркемнәрдә фикерләшәбез. | Укучылар таблицаның икенче ягына тамгалар куеп чыгалар. Аермаларны бер укучы аңлата |
| | - **Дәреслек белән эшлибез. 129 нчы биттәге 6 нчы сорауны карыйбыз.** | 6 нчы сорау буенча һәр укучы үз фикерен әйтә. |
| **III. Ныгыту**<br>**Максат:** белемнәрне ныгыту. | - **Проект эше.**<br>- 1.Беренче төркем “Яхшылык”, икенче төркем “Начарлык” темасына проект эшли. Дәрестә алган белемнәребезне проект эшендә кулланабыз.<br>- 2. Бер укучы проектны яклый<br>- 3.Укучылар бер-берсенең проектын бәяли. | Проект эше эшлиләр<br>Бер укучы проектны яклый<br>Укучылар проектларны бәяли, билгене аңлата. |
| **1.** 1. **Өй эше бирү.**<br>**Максат:** укучылар ның шәхси мөмкинлекләре н күздә тотып өй эшен өч | Фаил Шәфигуллинның “Акмөгез” хикәясе буенча сыйныфтан тыш укуга әзерләнергә<br>1) Фаил Шәфигуллинның “Акмөгез” хикәясен укырга<br>2) Фаил Шәфигуллинның “Акмөгез” хикәясе буенча план төзергә<br>3) Фаил Шәфигуллинның “Акмөгез” хикәясенә характеристика язарга | Өй эшен язып алалар |

| | | |
|---|---|---|
| дәрәҗәдә бирү. | | |
| 2.**Йомгаклау рефлексиясе**<br>**Максат:** дәрестә башкарган эшләргә нәтиҗә ясау. | - Укучылар, бүген дәрестә нәрсәләр белдегез?<br>- Дәрескә нинди максат куйган идек?<br>- Максатыбызга ирештекме? | - Укучылар нәтиҗә ясый. |
| 3. **Дәрескә гомуми бәя кую.**<br>**Максат:** дәрескә һәм үзеңә гомуми бәя кую, укучыларны бәяләү. | Укытучы укучылар куйган билге белән килешү-килешмәвен белдерә. | Укучылар бәяләү карточкалары нигезендә үзләренә билге куя. |

**Тест**

**1.Малайга әнисе суны кайдан алып кайтырга куша?**
1)ерактагы инештән
2)бакчадагы коедан
3) тау артындагы чишмәдән
**2.Малай әнисенә ничек җавап бирә?**
1) “Суны иртән тору белән алып кайтып куйсаң булмый идемени?”
2) “Тукта, мин бераз уйныйм әле”
3) “Хәзер, әнием, мин тиз генә алып кайтам”
**3.Кояшның каралу сәбәбен әнисе ничек аңлата?**
1) “Кемдер бу дөньяда изге гамәл кылган булырга тиеш”
2) “Кемдер бу дөньяда ялган эш кылган булырга тиеш”
3) “Кемдер бу дөньяда игелекле эш кылган булырга тиеш”

**Үзбәя картасы**_________________________________________________
(укучының фамилиясе)

| Бирем | Бәяләү нормасы | бәя |
|---|---|---|
| Төркемнәрдә эшләү | Бик яхшы – 3 балл<br>Яхшы – 2 балл<br>Канәгатьләнерлек – 1 балл | |
| тест | Бик яхшы – 3 балл<br>Яхшы – 2 балл<br>Канәгатьләнерлек – 1 балл | |
| Анализ өлешендә катнашу | Бик яхшы – 3 балл<br>Яхшы – 2 балл<br>Канәгатьләнерлек – 1 балл | |
| Эй ар гайд, Фикер алышуда катнашу | Бик яхшы – 3 балл<br>Яхшы – 2 балл<br>Канәгатьләнерлек – 1 балл | |

| | | |
|---|---|---|
| Дәреслектәге сорауларга җавап | Бик яхшы – 3 балл<br>Яхшы – 2 балл<br>Канәгатьләнерлек – 1 балл | |
| Проект эшендә катнашу | Бик яхшы – 3 балл<br>Яхшы – 2 балл<br>Канәгатьләнерлек – 1 балл | |

# ШӘҖӘРӘ – КИЛӘЧӘККӘ ТӘРӘЗӘ

*Габделхаков Булат Зәбир улы,6 сыйныф*
*Фәнни җитәкче - Габделхакова Альфира Марсиловна,*
*МБГУ "ТР Саба муниципаль районы*
*Курсабаш төп гомумбелем бирү мәктәбе"*

## I. Кереш өлеш

Шәҗәрә ул - үткәннәрдән
Киләчәккә тәрәзә.
Һәр халыкта, һәр заманда
Шәҗәрәдә дәрәҗә.
Дамир Гарифуллин

Бу сүзләрне күренекле башкорт әдибе Зиһат Солтанов әйтсә, Башкортстанның халык шагыйре Кадим Аралбай исә "Ал бер үрнәк—бал кортлары төзи кәрәз, син дә ятма: кор ояңны, үр шәҗәрә" дип, безне нәсел-нәсәбебезне белергә, туганнарны, тамырларыбызны барларга чакыра.

**Актуальлек.** Әйе , чынлап та , үзеннең үткәнеңне белми торып киләчәкне төзеп булмыйдыр ул. Гомумән, татар халкында җиде буын бабаңны белү фарыз гамәлләрнең берсе булып санала. Кеше җирдә үзенең кыска гына гомере эчендә барысына да өлгерергә, барын да танырга, белергә, изгелекләр эшләп калырга, сөенергә, шатланырга, кайгы-хәсрәтне җиңеп чыгарга һәм, иң мөһиме, үзе турында киләчәк буынга якты истәлек калдырырга тиеш.Менә шуның өчен дә мин тарихыбызны барлау,буыннар чылбырын ялгауны үземнең изге бурычым дип санадым һәм менә шушы изге эшкә алындым.

**Эшемнең максаты**: ата – бабаларның нәсел тарихларын белү, үз нәселеңнең шәҗәрәсен җыю, туплау, эзләнү. Тупланган мәгълүматларны эшкәртү, өйрәнү, нәсел шәҗәрәсен төзү.

Нәрсә соң ул шәҗәрә? Гарәп теленнән кергән "шәҗәрә "сүзе агач дигән мәгънәне белдерә.Буыннарның өзлексез алмашынып торуын ботаклы агачка охшатып төзелгән шәҗәрәләр язу,нәсел шәҗәрәсен төзү гадәте борынгы заманнар да ук халыкларда билгеле булган. Шәҗәрә төзүне мин тарихи материалларны өйрәнүдән башларга булдым , ә алар шактый. Бәхетемә, авылыбызда үткәнебез һәм киләчәгебезгә битараф булмаган Мәшүдә әбием исән әле. Ул миңа әби – бабайларым турында материал тупларга ярдәм итте. Шуларга нигезләнеп мин дә гаиләбез шәҗәрәсен төзедем.

## II . Төп өлеш

### 1.Авылым -күңелем бишеге

Мин , Габделхаков Булат Зәбир улы, Саба районы Өтернәс авылында дөньяга килгәнмен. Эзмә, Өтернәс һәм Иләбәр авыллары янында, Мишә елгасының югары агымы бассейнында XIV - XVI гасырларга караган һәм моңарчы өйрәнелмәгән истәлекләр –Эзмә һәм Өтернәс шәһәрлекләре, Өтернәс каберлеге урнашкан. Калатауда археологлар,КДУ һәм ТДГИ студентлары - жирле халык һәм житәкчелек ярдәмендә мәрмәр тактадан истәлек обелискы урнаштырган. Анда латин хәрефләре белән мондый юллар язылган: "1553-1554.

Мишә-Тамак –Калатау– Иләбәр. Явыз Иван гаскәрләре тарафыннан юк ителгән Өтернәс шәһәрлеге нигезе. Шәһитләргә Аллаһының рәхмәте булсын". Менә шушы Өтернәс шәһәрлеге урыннынан ерак түгел генә урнашкан Өтернәс авылында туганмын һәм шунда яшим мин.

**2. Тамырларым нык, киләчәгем өметле.**

Эш барышында тамырларымның шактый нык һәм зыялы булуын аңладым. Әнием һәм әниемнең әнисе ярдәме белән мин үземнең нинди данлыклы нәселдән икәнлегемне белдем.

Безнең нәсел башы әниемнең әнисе ягыннан Галиәкбәр бабайдан башлана.

Аның Җамали исемле бертуганы да булган. Галисгар Галиәкбәр улы Камалетдинов Казан шәһәрендә туа. Әбием сөйләвенчә, аның Габдрахман һәм Зәйнәп исемле туганнары да була. Галиәсгар Галиәкбәр улының Шәмсетдин исемле улы булган. Ә инде аның улы Тәһаветдин бабай, аның карчыгы Сәхипкамал минем әниемнең әбисенең әти- әнисе булганнар. Ягъни, Тәһаветдин бабай, аның карчыгы Сәхипкамалның балаларының берсе- Миңлегөл исемле булып, ул минем әниемнең әбисе булган. Аның ире Габбас исемле булган. Миңлегөл әбиемнең Өммегөлсем исемле кыз туганы да булган. Аның ире Исламгали исемле булган. Алар Саба районы Курсабаш авылында яшәгәннәр. Миңлегөл әбием Арча районы Сикертән авылында туып- үскән һәм Арча районы Мөрәле авылына килен булып төшеп, шунда гомер иткән. Аларның биш балалары туып, икесе генә исән-сау үскән. Аның берсе Мәшһүдә исемле (ул минем әбием була), энесе Мәгазь исемле булган. Кызганыч, ул бик яшьли үлеп киткән. Мәшһүдә әбием Арча районы Мөрәле авылыннан Саба районы Курсабаш авылына килен булып төшкән. Бабаем Марсель исемле. Аларның өч балалары туган: Альфира, Эльмира һәм Илфар. Альфира Марсель кызы ул- минем әнием була. Ул 2004 елда Саба районы Өтернәс авылына килен булып төшеп, әтием Зәбир белән тормыш корып җибәрәләр. Ә инде 2005 елда мин – Булат Саба районы Өтернәс авылында дөньяга аваз салганмын. Менә шундый мәгълүматларны өйрәнгәннән соң, мин үземнең зыялы нәселнең дәвамчысы икәнлегемне аңладым. Әтием Зәбир данлыклы үткәне Явыз Иван гаскәрләре тарафыннан юк ителгән Өтернәс шәһәрлегенә барып тоташкан , минем яраткан туган авылым булган Өтернәс авылыннан булса, әниемнең нәсел җепләре бик тирәнгә китеп, Галиәсгар Камалга барып тоташуы белән мин бик горурланам.

**III. Йомгаклау**

Бу эзләнүләрдән мин нәселем турында бик күп нәрсәләр белдем. Нәселемнең нинди зур, горурланырлык бай тарихы бар икән бит. Нинди генә авыр чорда яшәсәләр дә, алар төшенкелеккә бирелмәгәннәр, һәрчак алга атлаганнар, батыр, горур булып калганнар. Әби-бабаларыбыз мирасын,тәрбиясен буыннан-буынга тапшыру,нәселебез шәҗәрәсенә тап төшермичә яшәү- безнең бурычыбыз.Үткәннәрне барлап, киләчәккә күз төбәп яшәргә кирәк. Намусыбызны тапламыйча, вөҗданыбызга хыянәт итмичә һәм инде нәсел шәҗәрәбезне өзмичә гомер итәргә тырышсак иде.

*Кулланылган чыганаклар һәм әдәбият*

1.Тәлгат Нәҗмиев . Сабаларда эчәр суым булгач.-К, 2006, 100-101 б.
2.Тәлгат Нәҗмиев, Мәгъсум Хуҗин . Яшә, Саба-Йорт.-К, 1999, 209-210 б.

## БӨЕК ҖИҢҮНЕҢ КАДЕРЛЕ ЙӨЗЛӘРЕ

*Габдрахманова Айсылу Илфар кызы,10 сыйныф*
*Фәнни җитәкче - Габдрахманов Илфар Габделхай улы,*
*Балык бистәсе районы“Югары Тегермәнлек УГБМ”*

### I.Кереш

Дөньяда яшәргә һәм башкалар рәтендә
гомер сөрергә теләгән милләт үзенең
үткән көннәрен белсен һәм үз тарихы
белән дус булсын. (Ризаэддин Фәхреддин)

Минем исемем Айсылу, фамилиям Габдрахманова. Хәзерге көндә Балык Бистәсе районында урнашкан Югары Тегермәнлек урта гомуми белем бирү мәктәбендә 10 сыйныфта белем алам. Әби-бабаларым, әти-әнием шушы авылдан. 8 сыйныфтан бирле шушы тема астындагы эзләнү эшен алып барам, елдан-ел гаилә тарихы белән бәйле зур ачышлар ясыйм. Бу эштә миңа әтием, тарих укытучысы Габдрахманов Илфар Габделхай улы булышлык итә. Әби-бабаларның, күршеләрнең, туганнарның истәлекләре, әти Татарстан Милли архивыннан алып кайткан документлар, “Сугышчан һәм хезмәт даны” мәктәп музее материаллары миңа әлеге хезмәтне башкаруда ярдәм итәләр.

Эзләнү эшенең җөп максаты әлбәттә инде гаиләм тарихын өйрәнү. Минем уйлавымча һәр гаилә Ватаныбыз тарихында кечкенә генә булса да урын алып тора. Ата-бабалар тормышын, нигез, урам, мәктәп, авыл тарихын өйрәнми торып Россия, Бөтендөнья тарихын өйрәнү бик авыр булыр иде. Изге бурычыбыз да – үз гаилә тарихын өйрәнү.

Бөек Ватан сугышы Ватаным тарихында зур эз калдырган кебек ул гаиләм тарихында да тирән буразналар сызып калдырган.... Югары Тегермәнлек авылыннан фронтка 599 кеше киткән, шуларның 413 һәлак булган. Әлеге хезмәтнең дә бурычы сугышта катнашкан бабамнарның фотосүрәтләрен табып, йөзен күз алдына китереп, гаилә тарихының шул чорын язу.

### II.Төп өлеш

#### 1.Бөек Ватан сугышы чорында авылым Югары Тегермәнлек

Бөек Ватан сугышы турында язмалар, хезмәтләр Җиңү көне ергагайган саен күбәя. Вакыт үтү белән ул чор вакыйгалары төрле формада кайтаваз булып кире әйләнеп кайта. Сугышның илгә нинди зур зыян салганын, кешеләргә фаҗига алып килгәнен раслап утырасы юк. Шул чор шаһитлары аның турында безгә көн саен диярлек искәртеп торалар. Сугыш һәм тыл ветераннарының истәлекләре Бөек Ватан сугышы елларының нинди авыр булганлыгы турында сөйли. Бу хезмәтемдә мин документларга таянып, Югары Тегермәнлек авылы мисалында саннар аша югалтуларның никадәр зур булганын күрсәтеп китәсе килә.

Һәр дәүләтнең төп байлыгы булып аның халкы тора. Элек электән дәүләтебездә халык саны артуга зур игътибар биргәннәр. Әтием сөйләве буенча ул җиденче бала булып туганнан соң гаиләгә дәүләт тарафыннан зур суммада акча бүлеп бирелгән. Бабам Габдрахман шул акчага бөтен гаиләсен киендергән, әле аннан соң да шактый акчасы калган (элеккеге вакытта дәүләт туган бала өчен матди ярдәм күрсәткән. Беренче баладан соңгыларга күбрәк саен акча бүлеп бирелгән). 1939 елгы мәгълүматлар буенча Югары Тегермәнлектә 1938 елда 2037 кеше исәпләнгән, ә 1949 бу сан 1411 не тәшкил итә. Ягъни 10 ел эчендә авыл халкы 626 га кимегән (31%). Бу искитәрлек сан. Ел саен балалар күп тууга карамастан сугыш чоры белән бәйле, авылым кешеләре шушы күләмдә кимегән. Әле бу сан эчендә төп иң көчле ир-егетләр тора. Бу урында авылда күпме бала туганлыгын әйтеп китәсе килә. 1939 елда 58 булса, 1940 елда 38, 1941 – 23, 1942 – 24, 1943-14, 1944 – 6, 1945-9, 1946-24, 1947- 25, 1948 елда 29 бала туган. Барлыгы 250 бала.

Бөек Ватан сугышы кырларында Югары Тегермәнлектән 599 кеше катнашып шуларның 413 һәлак була (69%). Мондый саннар башка авылларда бардырмы юкмы, ләкин

бу бик зур сан булуы һичшиксез. Үлүчеләр саны бигрәк тә күп булуы аерым игътибарга лаеклы. Тегермәнлек халкы элек-электән бөек шагыйребез әйтмешли сугышта юлбарыстай булса, тыныч тормышта атка караганда да тырышып эшләгән.

**III.Бәһманов Габдрахман бабай һәм аның гаиләсе**

Әти ягыннан бабам Габдрахман 1895 елда Югары Тегермәнлектә дөньяга килә. Татарстан Милли архивыннан әтием алып кайткан метрика кенәгәсендә аның турында мәгълүмат алып була. *204 нче фонд 6 тасвирламаның 517 нче* номерлы чыганакта Габдрахман бабайның 1895 елның 12 апрелендә (иске стиль буенча) туганлыгы язылган. Атасы Бәһман Сафиулла улы, әнисе Шәмсеруй Хөснетдин Галиәкбәр кызы.



| | | | |
|---|---|---|---|
| 22 | Габдрахман | 12 | ат. крест. Бәһман Сафиулла улы |
| | | апр | ан Шәмсеруй Хөснетдин Галиәкбәр кызы |

Соңрак бу гаиләдә Миннегариф һәм Ханнан туа. Габдрахман бабам олы яшьтә булуга карамастан 1943 елда сугышка алына. Аңа кадәр энеләре киткән була. Миннегариф улы Хәбибрахман да яу кырларында ятып калалар. Ханнан пленга эләгә, исән-сау кайтып Украинада төпләнә, гаилә кора, ерак туганнарым хәзер Днепр (элеккеге Днепропетровск) шәһәрендә яшиләр, милләтләре буенча украиннар.



Габдрахман бабам Бәһманов (1895-1963)



СПИСОК



Югарыда Мемориал сайтыннан (http://www.obd-memorial.ru/) алынган документ копиясе.



Ханнан бабай

Әлеге югарыдагы булган фотолар гаилә альбомыннан алынды. Әйткәнемчә, Габдрахман бабамның тагы бер энесе Миннегариф булган. Аның фотосы юк иде. Узган, 2017 елда әти аның оныкларын эзләп тапты. Алар хәзер Казахстанда, Астана шәһәрендә яшиләр. Миннегариф һәм аның улы Хәбибрахманның паспортлары Раушан апа Арыстанбеков гаиләсендә саклана икән. Шулай итеп сугышта катнашкан барлык Бәһмановларның фотоларын таба алуга ирештек, аларның йөзләрен күз алдына китерә алабыз.






Миннегариф Хәбибрахман

Бәһманов Габдрахман бабайның дүрт улы өч кызы була. Төпчеге- әтинең әтисе Габделхай бабай.



Габделхай бабай (1936-1995)

Дүрт улының икесе Бөек Ватан сугышында катнаша. 1918 елгы Мәннан абый түбәндәге фотода арткы рәттә сулдан 5 нче.



Икенче улы Нуретдин. Ул 1926 елгы, 18 яшендә сугышка алына. Бәхеткә каршы Габдрахман бабай үзе дә, ике улы да сугыштан исән-имин кайтуга ирешәләр.



Габдрахманов Нуретдин

**3.Бертуган Сафиуллиннар**

Бертуган Сафиуллиннар - Зиннәтулла, Кәримулла, Шәфигулла Бөек Ватан сугышы кырларында һәлак булалар. Зиннәтулланың 1941 елның 21 маенда Фатыйма апа белән никахлашкан язуы Гәрәев Илшат гаиләсендә кадерләп саклана. Яшь гаилә тыныч тормышта бер ай гына яшәп кала. Кәримулла исемлесе минем Фәүзия әбиемнең бабасы инде.



ECKE EŞLƏR
НАРОДНЫЙ КОМИССАРИАТ

AXLЬQ KOMISSARIATЬ
ВНУТРЕННИХ ДЕЛ СССР

Graƶdanlьq xəlә aktlarь ьylege  Отдел [illegible]тов Гражданского Состояния

[illegible]KAX TURЬNDA TANЬQLЬQ
СВИДЕТЕЛЬСТВО О БРАКЕ
№ 2

Şiamp urnь
Место для штампа

Gr. Гр. [illegible]
(familia) (фамилия)
(isem) (имя) (atasьnьn isemе) (отчество)

Gr-ka гр-ка [illegible]
(familia) (фамилия)
(isem həm atasьnьn isemе) (имя и отчество)

Nikaxlandьlar həm şul turьda nikax turьndaqь graƶdanlьq xəlә aktlarь knagasenə jazьlьb
вступили в брак, о чем в книге записей актов гражданского состояния о браке произведена соответствующая запись.

(ьl, aj) həm (kiлөn, jazu həm səƶfrlər белән) (прописью и цифрами год, число и м-ц)

(nikaxlanqannan sonqь familialərе) (фамилия после заключения брака) (xatьn) (она)

ZAGS bjurasь mediro
Зав. бюро ЗАГС

Eş başqarucь
Делопроизводитель

М. П.

477-9

язылышу кәгазе



Зиннәтулла



Әтинең бабасы Кәримулла. 1913 елда туган. Маһирә әбигә өйләнгән. 1937 елда әби Фәүзия, 1939 елда аның энесе Ясәви туган. Кәримулла бабай 1945 елның февралендә һәлак була.



Шәфигулла Сафиуллин

Өч бертуган Сафиуллиннар Бөек Ватан сугышы кырларында батырларча сугышып, ятып калалар.

**4.Галимовлар**

Әтиемнең әбисе Маһирә әбием безнең белән яшәде. 97 яшендә, 2011 елда мәрхүмә булды. Аның ире-минем ерак бабам Кәримулла 1945 елның февралендә Бөек Ватан сугышында һәлак булган. Маһирә әбинең кыз фамилиясе Галимова. Маһирә әбинең энесе Нуретдин, абыйсы Фәттахетдин сугышта һәлак булалар. Бары тик абыйсы Гөлметдин генә исән-сау әйләнеп кайта.

 


Маһирә әбинең сугыштан исән кайткан абыйсы.




Мин Маһирә әбием белән

## III.Йомгаклау

Күптән башлаган башлаган эшем уңышлы гына дәвам итә. Әтием булышлыгы белән мин үземнең әби-бабаларымның Бөек Ватан сугышы белән бәйле тарихын өйрәндем, алай гына түгел аларны күз алдына китерерлек итеп фотосүрәтләрен урнаштырып бер хезмәт булдырдым. 2 класста укучы энем Әмиргә дә бу материал киләчәккә булышыр дип уйлыйм.

Үткән тарихка сәяхәт кызыклы да, катлаулы да эш. Мин бу хезмәтне башкарган вакытында үз нәселемнең зур, эшкә кыю, куркусыз икәнлеген аңладым. Үткәннәрне барлап, киләчәк өчен зур байлык калдыруым белән чиксез горурланам.

Исәннәрне барлыйк, исән чакта.
Үлгәннәрне барлыйк,
Тукталыйк та зират янында.
Тыныч йокы телик
Кире кайтмаска дип киткәннәргә.
Исәннәрне барлыйк!
Үлгәннәрне барлыйк!
Изгелекләр кылыйк барчасына,
Яшәүнең бит мәгънәсе дә шунда!

*Кулланылган әдәбият исемлеге һәм чыганаклар*

1. Габдрахманов И.Г. Югары Тегермәнлек:җирләре, халкы, тарихы. -Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Тарих институты басмаханәсе, 2007.-256 бит

2. Габдрахманов И.Г. Югары Тегермәнлек:совет чоры.- Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Тарих институты басмаханәсе, 2008.-420 бит

3. Габдрахманов И.Г. Шушы яктан, шушы туфрактан без. - Казан: “Яз” нәшрияты, 2017.- 412 бит

4. Татарстан Милли архивы 204 нче фонд 6 тасвирламаның 517 нче эш кенәгәсе

5. http://www.obd-memorial.ru/

# КЕЧЕ ВАТАНЫМ ТАРИХЫ

*Габдрахманов Илфар Габделхаевич,*
*Балык Бистәсе муниципаль районы*
*“Югары Тегермәнлек УГБМ”нең*
*тарих укытучысы*

Туган якны өйрәнү һәм саклау һәрбер гражданның изге бурычы. Россия Федерациясе Конституциясенең 44 статьясының 3 өлешендә әлеге дәүләттә яшәүче кешенең тарихи һәм мәдәни нәселне сакларга тиешлеге әйтелә. Туган якны өйрәнүгә аның табигате, тарихы, гореф-гадәтләре һәм мәдәнияте керә. Бу хезмәттә без туган як тарихын өйрәнүгә тукталып китербез. Туган якны икенче төрле кече Ватан дип атап йөрткәнгә күрә программаны “Кече Ватан тарихы” дип атадым. Аның максатын һәм бурычларын ачыклап, нинди юнәлешләрдә һәм формаларда кирәкле дәрәҗәдә эшләргә кирәклеген ачыкларга тырышырбыз.

Туган якны өйрәнүнең беренче хезмәтләре XV-XVI гасырларга карый,ул чордагы елъязмаларда чагылыш таба. XVIII гасырның уртасында Россия өлкәләрен сүрәтләгән беренче хезмәтләр күренә. Шул ук гасырның икенче яртысында бу өлкәдә уңай күренешләр күзәтелә. 1777 елда, өлкә реформасы үткәрелү сәбәпле, Сенат бөтен губерналарның топографик сүрәтләнешен эшләргә кушып указ бирә. Туган якны өйрәнүдә М.В.Ломоносовның да роле бик зур. Россиянең беренче географик атласын эшләгән вакытта ул бөтен губерналарга махсус анкета җибәрә.Анда һәр өлкә буенча тарих һәм халык яшәеше, табигый байлыклар буенча сораулар кергән була. Россиядә туган якны өйрәнү үсешендә ике юнәлеш билгеләнә: фәнни һәм укыту. 1918 елда РСФСРның бердәм хезмәт мәктәпләренең нигезләмәсе кабул ителә. Туган якны өйрәнүдә төп рольне укучылар уйнарга тиеш була. Туган якны өйрәнү белән галимнәр белән берлектә укучылар шөгыльләнә ала. Тикмәгә генә инде, соңрак, академик Д.С.Лихачев болай дип билгеләп үтми: ” Бу (туган якны өйрәнү) фәннең массакүләм төре: материаллар җыюда зур галимнәр белән янәшә укучылар да эшли.”

Яңа Россия чорында туган якны өйрәнү гомүм дәүләт күренешенә әверелде. 1990 елның апрелендә Россия туган якны өйрәнүчеләр союзы төзелә. Аның тарафыннан комплекслы программа кабул ителде. Ул үз эченә түбәндәгеләрне ала:

- Теория һәм туган якны өйрәнү фәне тарихы;
- Россиянең юкка чыккан һәйкәлләре;
- Елъязмалар;
- Россиянең мәдәни учаклары;
- Күренекле якташлар;
- Мәктәптә туган якны өйрәнү;
- Туган якны өйрәнү музейлары.

Мәктәпләрдә туган як тарихын өйрәнү нык үзгәрешләр кичерде. Болар барысыда яхшы якка. Әлеге уңай тенденция РФ нең “Мәгариф турында” законы нигезендә мәктәпләрдә милли-региональ компонент кертү белән бәйле. Мәктәпләрдә туган як тарихын өйрәнүгә бик зур игътибар бирелә башлады. Атаклы белгеч А.Е.Сейненский туган як тарихын өйрәнүне төрле концентрларга бүлә.

1.Минем гаилә.Шәҗәрә.

2.Туган мәктәп.Аның тарихы һәм традицияләре.

3.Авыл(шәһәр): элеккесе, хәзергесе, киләчәге.

4.Район тарихы.

5.Өлкә тарихы.

Бу концентрлар бербөтенне тәшкил итәләр, алар арасында аерма томанлы гына. Мисал өчен, шәҗәрәне өйрәнгән вакытта укучы мәктәп, авыл, район, өлкә тарихына мөрәҗәгать итә. Шул ук вакытта, киресенчә, гомуми тарихны өйрәнгәндә һәрбер гаиләнең дәүләт тарихына катнашы бар икәнлеге ачыклана.

Дөньяда кешелек үсеп бару юнәлешендә хәрәкәт итә, кечедән олыга таба күтәреләбез. Икенче төрле әйткәндә, җиңелдән авырракка. Туган як тарихын өйрәнгән вакытта да укучылар билгеле булган вакыйгалардан, билгесез булганнарны ачырга өйрәнергә тиештер дип уйлыйм.

Кече Ватан тарихын өйрәнгәндә нәрсәләргә игътибар итергә икән соң ?

1. Гуманлы белем бирү. Ягъни, нинди дә булса эшчәнлектә төп урынны аерым бер кеше алып торырга тиеш. Кешелеклелек, әхлаклылык-иң беренче алга куелган бурыч. Шунысын әйтеп китергә кирәк, атаклы шәхесләр белән беррәттән гади якташлар тарихы да зур урын алырга хокуклы.
2. Аерым бер социаль төркемнәр өйрәнелергә тиешле.
3. Шул төбәктәге төрле милләтләрнең тарихына, мәдәниятенә тигез рәвештә игътибар бирергә кирәк.
4. Билгеле бер төбәк кешеләренең башка өлкәләр белән элемтәләрен барларга.
5. Дин тарихы.

Туган якны өйрәнүнең оештыру формалары:

1.Җирле материалларны Россия һәм республика тарихын өйрәнгән дәресләрдә куллану.

2.Гади мәктәпләрдә тирәнтен гуманитар фән өйрәнү.

3.Электив курслар.

4.Өстәмә белем бирү берләшмәләре(түгәрәкләр)

Бу программаны тормышка ашырганда түбәндәге таләпләрне үтәргә кирәк:

1.Методик

--туган як тарихы буенча системалы материаллар;

--эзтабарлык эше буенча бөтен методикаларны белү(библиотека, архив, экспозиция һәм экскурсия эшен белү кирәк);

--укучыларга туган як тарихы тематикасы буенча булган китап фондларын һәм интернетны файдаланырга өйрәтү.

2.Дидактик.

Дәресләрне үткәрү өчен :

--туган як тарихы буенча булган документларның копиясенең булуы;

--игътибар белән якыннан өйрәнер өчен көнкүреш әйберләренең берничә экземплярын булдыру;

--плакатлар, карталар, схемалар ясарга;

--якташларны сөйләтеп җыйган видео-аудио материаллар кирәк.

3.Кадр.

Электив курс укытучысы түбәндәгеләрне белергә тиешле:

--яшь үзенчәлекләренә карап, эшчәнлек өчен төп максат һәм бурычларны билгеләү, аларны тормышка ашыру;

-- сөйләү сәнгатенә ия булу;

--укучыларның белемнәрен анализларга, комментарий ясарга һәм бәя бирә белү;

--укучылардан җәмгыять үсешенең закончалыкларын һәм законнарны белүне таләп итү;

--танып белү эшчәнлеген активлаштыру, укучыларны иҗади күзалларга өйрәтү;

--мөстәкыйль рәвештә укучыларны төрле максатларга ирешүгә этәрү;

--тәрбияләнүче балаларны рефератлар һәм докладлар белән чыгыш ясарга өйрәтү.

4.Материаль-техник

Куелган максатларга ирешү өчен түбәндәгеләр кирәк:

--фотоаппарат;
--интернеттан файдалану һәм документларны язу өчен компьтер;
--видеокамера;
--папкалар, фотоальбомнар һәм канцелярия кирәк-яраклары;
--китаплар фонды.

Хәзерге вакытта мәктәптә туган як тарихын өйрәнүдә тиешле дәрәҗәдә эшләү өчен укытучының югары профессиональ белгеч булуы кирәк. Ул иң беренче чиратта локаль булган тарихны, чыганаклар, һәйкәлләрне белергә тиеш. Шул ук вакытта балаларны тарту өче чын энтузиаст булу кирәк. Бары тик туган ягын яраткан кеше генә укучыларга патриотик тәрбия бирә ала. Балык бистәсе районы Югары Тегермәнлек гомуми урта белем бирү мәктәбендә дә туган як тарихын өйрәнү кирәкле дәрәҗәдә дип әйтәсе килә. Эшчәнлек вакытында өч максат алга куела:

1.Укучыларда тирә-юнь дөньяда лаеклы урын таба алырлык күпкырлы шәхесләр тәрбияләү.

2.Үз туган як тарихын Россия тарихы контекстында өйрәнү. Уку процессында эзләнү, музей-оештыру күнекмәләрен булдыру.

3.Укучыларды гражданлык һәм патриотизм, Ватанны ярату, авыл һәм дәүләт белән горурлану тәрбияләү.

Бу максатларны тормышка ашырганда түбәндәге бурычлар хәл ителә:

1.Гаилә тарихын өйрәнү.Шәҗәрәне төзү.
2.Мәктәп тарихын өйрәнү.
3.Авыл һәм район тарихын өйрәнү.
4.Эзләнү эшләре алымнарын үзләштерү.
5.Туган як тарихы буенча материаллар җыю.
6.Укучыларны туган якның мәдәни һәм тарихи байлыклары белән таныштыру.

Бу максатларны һәм бурычларны үтәү өчен Югары Тегермәнлек урта мәктәбендә бөтен мөмкинлекләр дә тудырылган дип уйлыйм. 1975 елның 9 маенда ачылган "Сугышчан һәм хезмәт даны" музеенда туган авылыбыз тарихы турында бик күп материаллар тупланган. Меңгә якын экспонатларны өйрәнеп туган ягыбызның тарихын тулысынча диярлек күзалларга мөмкин. Шулар арасында соңгы елларда Татарстан Милли архивыннан алып кайткан документларның күчермәләре. Беренчел тарихи чыганакларны тотып карау, аны өйрәнү кайбер тарихчыларның хыялы булып тора. Ә мондый мөмкинлек безнең укучыларда бар һәм алар архив документлары белән кызыксынып танышалар. Музейда тупланган бөтен мәгълүматны да электив курс барышында файдаланып була дип уйлыйм.

Бу программа буенча белем алган укучылар үзләренә күп ачышлар ясаячаклар. Гаиләнең тарихын өйрәнгән вакытта шәҗәрәләрен төзеп киләчәк буыннарына ядкарь калдырачаклар. Мөселман-татар кешесе үзенең җиде буын бабасының исемен белергә тиеш. Бу электив курс нигезендә моңа ирешергә мөмкин. Шулай булгач укучылар рухи яктан баечаклар, алар инде горурланып җиде бабаның белән дип әйтә алачаклар. Курсны өйрәнгән вакытта моннан тыш укучылар:

- архив чыганакларын кулланырга өйрәнәчәкләр;
- шәҗәрәне ничек төзергә икәнлеген беләчәкләр;
- музей материалларын файдалана алачаклар;
- экскурсия үткәрергә өйрәнергә мөмкиннәр;
- туган як тарихын күзаллыйлар.

Электив курсны өйрәнгән вакытта журналга билгеләр куелмый. Балаларның белемен, аларның үзләштерүен ничек бәяләргә соң? Бу программаны үтәгән вакытта укучыларны кызыксындыру мөкинлеге бик зур. Мисал өчен: бабаларының исемнәрен барлаганда укучыларның берсе дә кырыйда калмаячак. Хәзерге яшь буынга бер сыйфат хас, ул да булса горурлык хисе. Берсе белеп икенчесе белмәгән очракта соңгысы меңгә ярылып булса да белергә тырышачак. Шәҗәрә нәкъ шундый очрак та инде ул. Шуңа күрә барлык укучылар нәсел җепләрен тоташтырып схемалар ясаячагына мин ышанам. Шәҗәрәдән тыш укучылар

эзләнү эшләре алып барып, авылдашлары белән аралашачаклар, олылар белән сөйләшергә, дискыссия алып барырга өйрәнәчәкләр. Апа-апаларының, әби-бабайларның балалар турында уңай фикере туар дип уйларга кирәк. Шушы иң югары бәя булыр дип уйлыйм. Кайбер ата-аналарның җиде буыннарын, авыл тарихын белмичә аны аларга балалары таныштыру үзе бер вакыйга. Һәм шуннан соң ата-аналар да балаларның бу эшенә югары бәя бирерләр дип уйлым.

Дәресләр вакытында укучылар түбәндәгеләрне белергә тиеш:

- гаилә тарихын;
- яшәгән урам тарихын;
- мәктәп тарихын;
- авыл тарихын;
- колхоз тарихын.

Укучылар түбәндәгеләрне эшли белергә тиеш:

- шәҗәрә төзи белергә;
- архив материаллары белән эшли белергә;
- элеккеге һәм хәзерге авыл карталарын чагыштыра белергә;
- эзләнү эше алып бару;
- музей материалларын уку-тәрбия процессында куллана белергә.

**Программа**

**Кереш.** Курсның максатлары һәм бурычлары. Туган якны өйрәнүчеләрнең эш үзенчәлекләре. Дәресләрне оештыру. Эшнең әһәмияте. Куркынычсызлык кагыйдәләре буенча инструктаж.

**Туган як тарихын өйрәнү фәне.** Фән буларак туган як тарихын өйрәнү. Өйрәнү объектлары. Туган як тарихын өйрәнү формалары. Музей экспозицияләре һәм фонды-туган як тарихын өйрәнү чыганаклары.

Практик эш.. Туган як тарихи объектлары белән таныштыру.

**Минем гаилә тарихы.** Гаилә тарихын өйрәнү.

Практик эш.. Шәҗәрә төзү.

**Минем урамым.** Музей материаллары аша урам тарихы белән танышу. Урам исеменең килеп чыгышын аңлату. Экскурсия үткәрү.

Практик эш. Урамда яшәүче өлкән кешеләр белән очрашып истәлекләр язып алу. Һәр нигездә яшәгән кешеләрне барлау. Фотоларга төшү. Альбом төзү.

**Мәктәп тарихы.** Музей һәм архив материаллары аша туган мәктәп тарихы белән танышу. Элекке мәктәпне тәмамлаучылар белән очрашып истәлекләрен язып алу.

Практик эш. Мәктәп чыгарылышларын барлап чыгу. Укучылар исемлеген төзеп, аларның хәзерге тормышын юлын ачыклау. Альбом төзү. Мәктәп тарихын матбугатта яктырту.

**Авыл тарихы.** Мәктәп музее һәм архив материаллары аша авылның килеп чыгу тарихы, исеме, үсеше белән танышу. Туган авылның киләчәген фаразлау. Дәресләрдә материалларны куллану.

Практик эш. Экскурсияләр үткәрү. Авыл эчендә йөреп материаллар җыю. Изге урыннарда булу. Фото,-видеоматериаллар булдыру. Авылның күренекле кешеләре белән очрашу үткәреп, истәлекләрен язып алу.

**Тематик план**

| | **Дәрес темасы** | **Максатлар** | **Төп сораулар** | **Төшенчәләр** | **Мөстәкыйль эш төре** |
|---|---|---|---|---|---|
| | **Кереш** | Электив курсның эшчәнлеге һәм бурычлары | | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | белән таныштыру | | | |
| | **Туган як тарихын өйрәнү фәне** | Туган як тарихын өйрәнү фәне белән таныштыру | | | |
| | **Минем гаилә тәрихы.** Генеологи я – ярдәмчел тарихи дисциплина | Генеолог ия фәне белән таныштыру | 1.Шәҗәрә нәрсә ул һәм аны ни өчен өйрәнәләр? 2.Тарихи белем системасында генеология. 3.Россиядә һәм Татарстанда шәҗәрәне өйрәнү тарихы. | Нәсел. Буын. Генеология. Шәҗәрә. Тарихи ярдәмчел дисциплинала р | Шәҗәрә өстендә эәли башлау |
| | **Минем гаилә тәрихы.** Шәҗәрәне төзү теориясе һәм методикасы | Шәҗәрә төзү методикасы белән таныштыру | 1.Шәҗәрә һәм аны төрле формада ясау. 2.Генеологик таблица. 3.Шәҗәрә агачы. 4.Буыннар тезмәсе. | Буыннар . Генеологик таблица. Шәҗәрә агачы. Буыннар тезмәсе. Нәсел башы | Нәсел агачын ясау |
| | **Дәрес темасы** | **Максат лар** | **Төп сораулар** | **Төшенч әләр** | **Мөстәкы йль эш төре** |
| | **Минем гаилә тәрихы.** Тел һәм матди генеологик чыганак | Телдән ничек мәгълүмат җыярга мөмкинлеген ачыклау | 1.Генеологик мәгълүмат һәм генеологик чыганак. 2.Телдән генеологик чыганак җыю үзенчәлекләре. 3.Телдән җыйган генеологик мәгълү-матны эшкәртү. | Генеолог ик мәгълүмат. Генеологик чыганак. Тел. Язма. Матди генеологик чыганак. Эпиграфика. | Нәсел агачын ясау |
| | **Минем гаилә тәрихы.** Язма генеологик чыганак | Тарихи чыганаклар белән таныштыру | 1.Тарихи генеологик чыганак:-елъязма-лар, разряд китапла-ры, шәҗәрә китапла-ры, халык санын алу материаллары. | Эпиграф ика. Генеологик досье һәм карточка. | Нәсел агачын ясау. Документларга анализ бирергә өйрәнү |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | 2.Гаиләч ыганак-лары: истәлекләр, язмалар, фотосүр-этләр, газета-журналлар.3.Язма чыганакларны җыю һәм системага салу. | | |
| | **Минем гаилә тәрихы.** Архивлар һәм архив чыганаклары | Архив эшчәнлеге белән таныштыру | 1.Россиядәһә мТатар станда архивлар һәм архив системасы. 2.Архивта гене-ологик чыганаклар: халык санын исәпкә алу материаллары. | Архив эше. Архив чыганаклар. | Нәсел агачын ясау |
| | **Минем гаилә тәрихы.** Исем һәм шәҗәрә | Антропо ни-мика фәне белән таныштыру, татар мсемнәренең кайдан килеп чыкканлыгын ачыклау. Балаларның үз исемнәренең мәгънәсен белергә булышу | 1.Антропоним ика – исемнәр турындагы фән. 2.Рус исем-фамилияләренең, кушаматларының килеп чыгышы. 3.Татар исем-фамилияләренең, кушаматларының килеп чыгышы. | Антропо ними-ка. Исем. Фамилия. Кушамат. | Балалар үзләренең исемнәренең мәгънәсен ачыклау |
| | **Минем гаилә тәрихы.** Кешеләр вакытны ничек исәпли | Ел исәпләре белән таныштыру | 1.Тарихта вакытны билгеләү ысуллары. 2.Христианнарда ел исәбе. 3.Мөселманна рда ел исәбе. | Тарихи вакыт. Хронология. Тәүлек. Атна. Ай. Ел. Гасыр. Эра. Дәвер. Чор. Һиҗри. Милади ел ис. | Хиҗри ел исәбе буенча эш |
| 0 | **Минем гаилә тәрихы.** Тамгалард ан – дәүләт символларына | Нәсел тамгаларын ачыкларга булышу | 1.Эмблемалар һәм гербларның килеп чыгышы. 2.Гербларны ясау кагыйдәләре. 3.Россиянең һәм Татарстанның дәүләт символлары. 4.Татар тамгалары. | Эмблема . Геральдика. Герб. Тугра. Тамга. | Нәсел тамгаларын ачыклау |
| 1 | **Минем гаилә тәрихы.** | Төрле чорда булган | 1.Тарихи география. | Тарихи география. | Нәселнең географик |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | Минем нәселнең географиясе | җирле административ бүленешне аңлату | 2.Топономикада тарихи исемнәр сандыгы.3.Нәсел-нәсебемнең таралып яисә туп-ланып яшәвендә миграция йогынты-сы.4.Җирле админи-тратив үзгәрешләр. | Топонимика. Миграция. Эмигрант. Диаспора. | картасын төзү |
| 2 | **Минем гаилә тәрихы.** Гаиләдә - һөнәрләр | Профориента-ция өстендә эш | 1.Тормыш-көнкүрештә һәнәрләр һәм синең аларга мөнәсәбәтең. 2.Ата-бабаңнарның хезмәттәге казанышлары. | Һәнәр. Профессия. Белгечлек. | Ата бабаларның һөнәрләрен ачыклау |
| 3 | **Минем гаилә тәрихы.** Минем шәҗәрәм | Балаларның шәҗәрәләре белән бер-берсен таныштыру | 1.Төрле рәвештәге генеологик таблица һәм шәҗәрә агачлары ясау. 2.Буыннар тезмәсен тикшерү һәм ядарту. 3.Шәҗәрә агачыннан – гаилә тарихына.4.Объективлык, фәннилек, толера-нтлык – галә тарихын язуда төп кагыйдәләр. | | Шәҗәрәләр буенча чыгыш ясау |
| 4 | **Минем урамым** Тегермәнлек урамнары | Тарихи карталар өстендә эш | 1.1795 елгы картада авыл урамнары. 2.1817 елгы картада авыл урамнары. 3.1879 елгы картада авыл урамнары. 4.Совет чоры карта-ларында авыл урамнары | Генераль план. | Тарихи карталар белән хәзерге авыл картасын чагыштыра белү |
| 5 | **Минем урамым** Урам исемнәре ни сөйли? | Элеккеге урам исемнәрен ачыклау, хәзе-рге урам | 1.Элеккеге урам исемнәре. 2.Хәзерге урам исемнәре нәрсә сөйли? | Брахау. | Урам исемнәре буенча мәгълүмат җыю |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | исем-нәренең килеп чыгуын ачылау | | | |
| 6 | **Мәктәп тарихы** Мәктәп оешу | Мәктәпнең беренчел эшчәнлеген тасвирлау | 1.Архив чыганакла-рында мәктәп та-рихы. 2.Совет мәк-тәбе ачылу тарихы. | Кадими мәдрәсә. Җәдиди мәдрәсә. | Мәктәп тарихы буенча ветеран укытучылардан истәлекләр җыю |
| 7 | **Мәктәп тарихы** Җидееллык мәктәп ачылу | Җидееллык мәктәп ачылу тарихы белән таныштыру | 1.Җидееллык мәктәп ачылу. 2.30-40 елларда мәктәп тормышы. 3.30 елларда белем һәм тәрбия биргән укытучылар | Ликбез. | Музей материалларын өйрәнү |
| 8 | **Мәктәп тарихы** Урта мәктәп | Урта мәктәп эшчәнлеге белән таныштыру | 1.Урта мәктәп ачылу 2.Мәктәп дирек-торлары. 3.Укытучылар | | Музей материалларын өйрәнү |
| 9 | **Авыл тарихы** Авыл исеменең чыгышы | Авыл исемнәре чыгышы тарихы белән таныштыру | 1.Тимерлек авылы исеме чыгышы. 2.Тегермәнлек авылы исеме чыгышы | Тимерлек. Тегермәнлек. | Өлкән авылдашлардан истәлекләр туплау |
| 0 | **Авыл тарихы** Авыл төзелү турындагы легендалар | Төрле легендалар белән таныштыру | 1.Тарихи чыганаклар. 2.Риваятьләр | Легенда. Риваять. | Өлкән авылдашлардан истәлекләр туплау |
| 1 | **Авыл тарихы** Казан ханлыгы руслар тарафыннан басып алынганнан соң безнең авыл | Казан ханлыгының руслар тарафыннан басып алынганнан соң татар халкының авыр тормышын күз алдына китерергә булышу | 1.Казан ханлыгының руслар тарафыннан басып алынуы 2. 1560 еллардагы тарихи чыганак. | | |
| 2 | **Авыл тарихы** Е.Пугачев җитәкчелегендә үткән фетнә | Фетнәнең башлану сәбәпләрен ачыклау | 1.1773-1775 еллардагы фетнә. 2. .Пугачев җитәкчелегендә үткән фетнә | Фетнә. | Вахит Имамовның китабы буенча мәгълүмат |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | чорында авыл һәм төбәк | | чорында авыл һәм төбәк | | туплау |
| 3 | **Авыл тарихы** XIXгасырда авыл: халык саны һәм перепись | XIXгасырда авылда күпме кеше яшәгәнлеген аңлату | 1.Халык санын алу мәгълүматлары. 2.”Ревизийская сказка”. 3.Тарихи карталар | “Ревизийская сказка”. Ревизия. Перепись. | “Ревизийская сказка” күчермәсе белән эш |
| 4 | **Авыл тарихы** XX гасыр башында Югары Тегермәнлек | XX гасыр башында Югары Тегермәнлек авылы тормышын тасвирлау | 1.Җирләре. 2.Халкы. 3.Халыкның шөгыле | Кәсеп. | Кыскача информация туплау |
| 5 | **Авыл тарихы** Мәчетләр тарихы | Мәчетләрнең тарихы, муллаларның язмышы белән таныштыру | 1.Мәчетләр тарихы. 2.Мәчетләрнең ябылуы. 3.Муллалар язмышы | Метрикә кенәгәсе. | |
| 6 | **Авыл тарихы** Колхоз төзелү | Күмәкләштерү чорының авыл халкы өчен нинди фаҗига алып килгәнлеген аныклау | 1.Совет хакимияте урнашу. 2.Колхоз оешу. 3.30 елларда авыл тормышы. | Колхоз. Совхоз. Күмәкләштерү. | Истәлекләр җыю |
| 7 | **Авыл тарихы** Бөек Ватан сугышында авылдашлар. | Бөек Ватан сугышы чорында авылдашларның хәрби батырлыгына бәя бирү | 1.Бөек Ватан сугышы кырларында авылдашлар. 2.Батыр якташларыбыз. 3.Барый Шәвәлиев батырлыгы. | Бөек Ватан сугышы. | Музей материаллары белән эш |
| 8 | **Авыл тарихы** Бөек Ватан сугышы чорында авыл | Бөек Ватан сугышы чорында авылдашларның тылдагы батырлыгына бәя бирү | 1.Авыл советы эшчәнлеге. 2.Колхоз томышы. | Заем. Фонд. | Истәлекләр җыю |
| 9 | **Авыл тарихы** “Хәтер” китабы | “Хәтер” китабы белән таныштыру | 1.Үлгәннәрнең каберен бел. 2.”Хәтер” китабы мәгълүматлары. | | “Хәтер” китабын анализлау |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 1-32 | **Авыл тарихы** XX гасырның икенче яртысында авыл һәм колхозның үсеше | XX гасырның икенче яртысында авыл һәм колхозның үсеше белән таныштыру | 1.Сугыштан соңгы еллар. Хуҗалыкны торгызу. 2.60-80 елларда колхоз тормышы. 3.Колхоз һәм авыл советы җитәкчеләре. 4.Хезмәт батырлары | | Фотографиялəр туплау |
| 3 | Музейда экскурсия | Музей, аның эшчәнлеге белән тирәнтен таныштыру | 1.Музей оешу тарихы. 2.Хәзерге музей советының эшчәнлеге. | | Музей материаллары белән мөстәкыйль танышу |
| 4 | Йомгаклау | | | | |

**Методик яктан тәэмин ителеш**

**Кереш һәм туган як тарихын өйрәнү фәне** темаларын үткән вакытта укучыларга лекция һәм музей буенча экскурсия үткәрелә.Укучылар эзтабарлык эшенә беренче тапкыр аяк баскан вакытта, шулай ук элеккеге елларда түгәрәк эшен яктырткан видео-язмаларны да кулланырга мөмкин. Алдан төзелгән фото-альбомнар да укучыларга ярдәм итәр.

**Гаилә тарихы**н өйрәнгән дәресләрдә укучылар укытучы җитәкчелегендә күбрәк иҗади эшлиләр. Һәрбер бала үзенең шәҗәрәсен төзи. Нәсел агачы компьюторда җыела алган кебек, кулдан да матурлап төрле формада урнаштырыла ала.

Укучылар үзләренең **урамнарын өйрәнгәннән** соң кечкенә генә конференция сыман эзләнү чарасы үткәрергә мөмкин.

**Мәктәп тарихын** барлаганда ветеран укытучылар белә очрашулар оештырырга була.

**Авыл тарихы**н өйрәнгәндә күбрәк җитәкче тарафыннан сөйләм теле белән һәм язма рәвештә мәгълүмат бирелә. Бу тема өйрәнелүнең нәтиҗәсе итеп кечкенә генә авыл тарихын тасвирлаган китапчык төзү булыр.

Шөгыльләнгәндә түбәндәге материалларны һәм техник чараларны кулланырга мөмкин:

-- диапроектор;
--фотоаппарат;
--магнитофон;
--телевизор һәм видеомагнитофон;
--интернеттан файдалану һәм документларны язу өчен компьютер;
--папкалар, фотоальбомнар һәм канцелярия кирәк-яраклары;
--китаплар фонды.

**Докладлар,рефератлар һәм проект эшләренең тематикасы:**

1.Минем гаилә Ватан тарихында.
2.Урамым тарихы
3.Мәчет каршында оешкан мәктәп
4.Мәчетләр тарихы (1, 2, 3 мәчетләр)
5.Авыл муллаларының язмышы
6.Авылыбызның җирләре

7.Югары Тегермәнлек чишмәләре
8.Колхозлашу чоры
9.Колхоз рәисләре
10.Авыл советы рәисләре
11.Мәктәп директорлары
12.Матросовчы якташыбыз
13.Бөек Ватан сугышы чорында туган авылым
14.Мәктәп тарихы
15. Әфганистан – йөрәк ярасы
16. Сугыш чоры балалары
17. Хезмәт ветераннары
18. Атаклы авылдашларыбыз

**Кушымта**

**Төшенчәләр:**

Нәсел. Буын. Генеология.Шәҗәрә.Тарихи ярдәмчел дисциплиналар. Буыннар. Генеологик таблица. Шәҗәрә агачы. Буыннар тезмәсе. Нәсел башы. Генеологик мәгълүмат. Генеологик чыганак. Тел. Язма. Матди генеологик чыганак. Эпиграфика. Генеологик досье һәм карточка. Архив эше. Архив чыганаклар. Антропонимика. Исем. Фамилия. Кушамат. Тарихи вакыт. Хронология. Тәүлек. Атна. Ай. Ел. Гасыр. Эра. Дәвер. Чор. Һиҗри. Милади ел исәбе. Эмблема. Геральдика. Герб. Тугра. Тамга. Тарихи география.

Топонимика. Миграция. Эмигрант. Диаспора. Һөнәр. Профессия. Белгечлек. Генераль план. Брахау. Кадими мәдрәсә. Җәдиди мәдрәсә. Ликбез. Тимерлек. Тегермәнлек. Легенда. Риваять. Фетнә. “Ревизийская сказка”. Ревизия. Перепись. Кәсеп. Метрикә кенәгәсе. Колхоз. Совхоз. Күмәкләштерү. Бөек Ватан сугышы. Заем. Фонд. Контрактование.

**Чыганаклар:**


1.Ашуров В.Н. и др. Историческое краеведение.-М.,1980
2.Кружковая работа по истории и обществознанию.-М.,1984
3.Матюшин Г.Н. Историческое краеведение.-М.,1987
4.Методика историко-краеведческой работы в школе.-М.,1982
5.Просстов М.П. Кружковая работа(сборник статей). М.,1984
6.Сейненский А.Е. Родной край : страницы истории. В помощь педагогу-краеведу. Преподование истории в школе. 1995.№ 4. С.61
7.Демин М.А. Научно-образовательный центр исторического краеведения.Преподование истории в школе. 1998. №5. С.56
8.Элькин Г.Ю., Огрызко З.А. Школьный музей. – М., 1972
9. Фокеева И.М. Национально-региональный компонент исторического образования.-Казань,2003
10.Фәйзелхак Ислаев “Шәҗәрәдә - ил тарихы”. Мәгариф. 2007. №9.65 бит.

## АНА ҖЫЛЫСЫ – КОЯШ ҖЫЛЫСЫ

*Гайсина Гөлфия Габделзөфәр кызы,*
*“Котлы-Букәш урта гомуми белем бирү мәктәбе”,*
*Балык Бистәсе районы*

Дәрес темасы: Ана җылысы – кояш җылысы

(Фәнис Яруллинның “Кояштагы тап” әкиятен өйрәнү. Сыйныфтан тыш уку дәресе, 5 нче сыйныф)

**Максат:**Фәнис Яруллинның “Кояштагы тап” әкиятен өйрәнү

**Планлаштырылган нәтиҗә**

– Фәнис Яруллинның “Кояштагы тап” әкиятен уку һәм анализлау;

– әсәрдәге геройны характерлап, аның турында фикер әйтә белү;

– әсәрнең эчтәлеген мөстәкыйль рәвештә үзләштерү һәм анализ ясау күнекмәләре булдыру;

– әкиятнең темасын, проблемасы, максатын мөстәкыйль билгели алу;

– әниләргә хөрмәт хисенә төшенү.

**Универсаль уку гамәлләре (УУГ)**

ШУУГ: яхшылык- начарлык кебек сыйфатларны тану, бәяләү;

ТБУУГ: дөрес нәтиҗәләр чыгару, гомумиләштерүләр ясый белү;

КУУГ: үз фикереңне телдән башкаларга төгәл һәм аңлаешлы итеп җиткерә белү;

РУУГ: уку мәсьәләсен фаразлау

**Төп төшенчәләр**: Әкият, матурлык, ямьсезлек, легенда, табигать образлары

**Предметара бәйләнеш:** Әхлак, география

**Дәрес планы**

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру**

1. Дәресне оештыру.

Балаларда яхшы кәеф тудыру.

− Хәерле иртә, балалар! Кәефләрегез әйбәтме? Көнне яхшы сүз белән башласаң, бөтен көнең яхшы үтәр, диләр. Әйдәгез әле, бер-беребезне яңа көн белән котлыйк.

**Укучылар теләкләр тели:**

− Яңа көн тынычлык алып килсен!

− Яңа көндә яңа "5"леләр алыйк!

− Әти-әниебезгә, дусларга ягымлы булыйк!

**- Мин сезгә уңышлар телим. Дәрестә игътибарлы булыгыз, бер-берегезгә ярдәм итегез, актив катнашыгыз.**

**<u>Мотивация (эшкә кызыксыну) тудыру.</u>**

–Укучылар, минем кулымда нәрсә?

– Кәгазь бите.

– Ул нинди төстә?

– Ак.

– Аның уртасында нәрсә бар?

– Кара тап.

– Әйдәгез, без бу тапны бозгыч белән бетереп карыйк. Эзе калдымы?

– Калды

– Ә хәзер штрих белән бозып карыйк. Штрих эзләре калдымы?

– Штрих белән бетергәнебез күренә.

– Әйе, һәр таптан беленер-беленмәс кенә эз калды.

Бу мисалны кеше тормышындагы нинди гамәлләр белән тәңгәлләштереп була?

– Кеше нинди дә булса начарлык эшли. Бу начарлыкны ул үзе дә онытып бетерә алмый, башкаларның да исендә кала.

**II.Уку мәсьәләсе кую**

– Димәк, укучылар, уйлап карагыз әле, без бүген сезнең белән нинди әдәби әсәр турында сөйләячәкбез?

- Ф.Яруллинның “Кояштагы тап” хикәясе турында.

- Дөрес ,укучылар. Сез өйдә әкиятне укып килдегез. Әкият турында сөйләшә башлаганчы аның авторы Ф.Яруллин турында бераз гына мәгълүматлы булыйк . Мин сезне аның тормыш юлы белән таныштырам.

Күренекле язучыбызга быел 9 февральдә 80 яшь тулды. Ф.Яруллин 1938 елда Татарстанның Баулы районы Кызылъяр авылында туа. Ул кечкенәдән әтисез кала. 1942 елда Ф.Яруллинга 4 яшь вакытта әтисе сугыш кырында үлеп кала. Әнисе Гафифә апа 6 баланы ялгызы тәрбияләп үстерә. Фәнис абыйга ачлыкны да, ялангачлыкны да күрергә туры килә. Үзләренең авылларындагы сигезьеллык мәктәпне тәмамлагач, 3 ел монтер булып эшли. Аннары Армия сафларына алына. Тормыш бик катлаулы ул, балалар. Кешеләрне зур сынау алдына китереп куя. Ф.Яруллин белән дә шулай була. Армиядә ул спорт белән мавыга. Спорт күнегүләренең берсендә турниктан егылып имгәнә. Гомерлеккә йөри алмас хәлдә кала. Аңа бу вакытта бары 20 яшь кенә була. Ул бик озак шифаханәләрдә ятып дәвалана. Моннан соң аның бөтен тормышы үзгәрә. Ул үзенең аянычлы хәле, язмышы белән көрәшеп яшәүгә күчә. Бу рәвешле яшәү Ф.Яруллиннан бик зур ихтыяр көче сорый. Ул үзен башкалар кебек үк кеше итеп сизү өчен аң-белемгә омтыла. Иң элек урта мәктәпне тәмамлый. Аннары читтән торып һәм бик күп көч куеп Казан дәүләт университетында белем алып чыга. Аның тирәсендә ярдәмчел, яхшы күңелле кешеләр була, аңа бик теләп ярдәм кулы сузалар, язмыш кочагына ташламыйлар. Ә иң зур ярдәмчесе, олы терәге әлбәттә - аның әнисе Гафифә апа була. Ана баланы тудыручы да, аңа һәрвакыт һич авырсынмыйча ярдәм итүче дә. Шуңа күрә язучы дөньядагы аналарның барысын да ярата. Бу темага бик күп шигырьләр яза.

-Дәресебезнең темасы да әниләр белән бәйле. Игътибар белән экранга карыйбыз. Экранда мәкальләр бирелгән.

Өйнең яме ана белән;

Ана җылысы – кояш җылысы;

Әни суккан авыртмый;

-Укучылар, бу мәкальләрне нәрсә берләштерә?

-Алар барысы да әниләр турында.

-Ә кайсы мәкаль сезгә бигрәк тә ошады, кайсы мәкаль сез укып килгән әсәргә ныграк туры килә?

- Ана җылысы-кояш җылысы.

-Ни өчен ана җылысы кояш җылысы белән чагыштырып бирелә? Әйдәгез шушы сорауга җавап эзлик әле.

**III Өй эше тикшерү.**

Ф. Яруллинның “Кояштагы тап” әкиятен бүлекләргә бүлеп сөйлик һәм аларга исемнәр бирик.

**Сүзлек өстендә эш (тәкъдим итешә)**

Каф тавы – Кавказ тавы

Тап -пятно

Шифалы – файдалы

Офык – горизонт

Шомлы – куркыныч

Мөлдерәмә - тулы

Яманлык – начарлык.

**Әсәрне өлешләргә бүлик һәм аларга исемнәр бирик.**

**Төркемнәрдә эш.**

1 нче бүлекне рольләргә бүлеп укыйлар. Бүлеккә исем бирелә.

Малайның әнисе авырый( АВЫРУ АНА)

2 төркем эчтәлеген сөйли. Бүлеккә исем бирелә

Малай әнисен алдый (ЯЛГАНЧЫ МАЛАЙ)

3 төркем 3 нче бүлеккә рәсем ясый, кыскача сөйли

Кояш елмаеп җибәрә (КОЯШТАГЫ ТАП)

**IV. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү**

**Сорауларга җавап бирү**

**-Кояшның каралу сәбәбен әни кеше ничек аңлата?** Шул урынны табып укыгыз.

(Укучылар: Кемдер бу дөньяда ялган эш кылган булырга тиеш, улым. Кояшны шул кеше өчен оялудан йөзе каралып чыккан.)

**Әсәрдән авторның чыгарган гомуми нәтиҗәсен табып укыйбыз**. (укучылар җавап бирә)

- Бер генә яманлык та эзсез калмый.

– **Дөрес, укучылар, дөньяда бер генә начарлык та эзсез калмый. Бу турыда татар халкында бер гыйбрәтле кыйсса да бар. Тыңлап китегез әле.**

Бер малай әнисе белән генә тора. Ул, улы начарлык эшләгән саен, рәшәткәгә бер кадак кага бара. Еллар уза, бала үсеп буйга җитә. Беркөнне ул кадакларга игътибар итә һәм әнисе янына килә. Әни, нигә син шулай күп итеп кадаклар кактың? - ди. Әнисе: “ Улым, менә син бер начарлык эшләгән саен мин бер кадак кага бардым. Күрәсеңме, ничаклы алар?” – ди. Улы уйга кала һәм гел яхшылыклар гына эшләргә сүз бирә. Шулай эшли дә. Менә ул да олыгая, әнисе дә карчыкка әйләнә. Әнисе янына беркөнне килә дә: “ Әни, кара әле, рәшәткәдә бер кадак та калмады. Мин яхшылык эшләгән саен берсен ала бардым. Начарлыкларыма каршы яхшылык эшләдем”, - ди. Ә әнисе болай ди: “ Улым, әйе син күп яхшылыклар эшләдең һәм, шулай итеп, начарлыкларыңны бетердең дә кебек, тик әнә, кара әле рәшәткәләргә, никадәр кадак эзләре. Аларның эзләре калган бит”, - ди.

**V. Белемнәрне яңа ситуациядә иҗади куллану һәм эзләп табу**

**-Әкияттә кемнәр катнаша? Төп образларны атагыз әле?**

-Малай һәм ана һәм кояш

- **Сезнең алда әсәрнең геройлары өч төркемгә аерып бирелгән. Аларга хас булган сыйфатларны тиешле рәткә урнаштырырга кирәк.**

эшчән, ялганчы, тырыш, ялкау, ягымлы, күзәтүчән, үзен генә яратучы, кайгыртучан, гафу үтенә, оялчан, үз хатасын таный, сабыр, миһербанлы, киң күңелле,яктылык чыганагы, елмая.

**-Димәк, ана образына нинди сыйфатлар хас?**

-Ана эшчән, тырыш, ягымлы, кайгыртучан, сабыр, миһербанлы, киң күңелле һ.б.

-Әйе, укучылр, барлык әниләр миһербанлы, киң күңелле, баласы өчен җанын бирергә әзер.

**-Малайга нинди сыйфатлар хас?Аның тәртибе сезгә ошыймы**? **Ни өчен ошамый?**

- Ялкау, әнисен тыңламый, алдый. Ул әнисе авырганда аңа ярдәм итми, бөтен дөньясын онытып, урамда уйный, әле тагын ялганлый да, әнисе кушкан чишмәдән су алып кайтмый.

**- Ул боларны начарлык эшлим дип эшлиме? Малайның яхшы сыйфатлары бармы?**

- Дөрес, ул үзенең ялгышын, гаебен таный. Дөньяда яшәгәндә, бөтен кеше дә ялгыша, ә балалар бигрәк тә. Иң мөһиме: ул ялгышны вакытында күреп, төзәтә белергә кирәк.

**- Ни өчен малай уенга бирелә?**

- Аның уйныйсы килә, әле ул кайсы эш мөһимрәк икәнен аңлап бетерми.

**- Сез малай урынында булсагыз нишләр идегез?**

-**Кояшка нинди сыйфатлар хас?** ( Кояш бар нәрсәне дә күрә: яхшылыкны да, яманлыкны да. Кояш бу әсәрдә малайның ялганыннан оялып карала, ә малай гафу үтенгәч, ул елмаеп җибәрә. Кояш ул- безне яшәтә, җылыта, безгә нур һәм яктылык бирә.)

- Кояш – символик образ. Ул – яктылык, матурлык билгесе. Кояш җиргә, хайваннарга, үсемлекләргә көч, җылылык бирә.

• Хәзер кояш сүзенә якынрак килик әле. Аның мәгънәсе аңлатмалы сүзлектә ничек күрсәтелгән икән?

• Кояш. 1. Без яшәгән планета – Җир һәм башка планеталарның әйләнеш үзәгендә торган зур күк җисеме – янар йолдызларның берсе.

2. Бәхет, шатлык, сөенеч чыганагы. (күчмә мәгънәдә.)

-Кояшта ни өчен таплар бар? География дәресләрендә бу турыданиләр өйрәндегез?

-Ни өчен Ф. Яруллин кояш образына мөрәҗәгать итә?

"Әнинең җылы кочагы" диләр. Әни дә безгә җылылык, көч, рәхәтлек бирә. Димәк, ана җылысы – кояш җылысы.

**Физкультминутка**

Кояш арыды, ял итә (кулларын партага куеп, башларын кул өстенә куеп йоклыйлар)

Кояш уяна, елмая.(торып басалар, кулларын югары күтәрәләр һәм өскә карыйлар)

Кинәт җил чыкты.(уңга, сулга чайкалалар)

Күк күкри башлады.(кул чабалар)

Яңгыр ява башлады(бармак очлары белән партага бәргәлиләр)

Яңгыр бетте, кояш балкый.(кулларны өскә күтәреп, тирән сулыш алалар һәм утыралар)

**- Сезгә өйдә кайчан күңеллерәк? Әни өйдә булгандамы яки ул югындамы?**

-Әни өйдә булмаса, бернинди ямь дә юк, бөтен дөнья караңгылыкка чумган кебек тоела. Фәнис Яруллин үзенең "Бушлык" дигән шигырендә шул турыда әйтә. Укучылар, сезгә шундый бирем. Партадаш иптәшегез белән киңәшеп, түбәндәге сорауга җавап эзләп карагыз әле:шигырь ни өчен "Бушлык" дип атала икән? "Бушлык". Фәнис Яруллин.

Өйнең эче яп – ялангач,
Белмимен әллә нигә?
Кайтып керәсе дә килми
Бүген бөтенләй өйгә.
Бөтен нәрсә үз урынында,
Тик җитешми әллә ни...
Әй, онытып торам икән:
Өйдә юк бүген әни!

- Әйе, укучылар, әни өйдә булмаганда, бик күңелсез, моңсу. Язучы юкка гына әни белән кояшны янәшә куймаган икән. Ә күктә кояш балкымаса, күңеллеме? Әйе, укучылар, без кояшлы көннәрне, кояшны яратабыз.

**Экранда бирелгән мәкальләрнең парларын табу һәм әниләр турында тагын нинди мәкальләр белүләре белән кызыксыну.**

| | |
|---|---|
| Әткәм- шикәр, | бала күңеле далада. |
| Ана җылысы- | газиз нәрсә булмас. |
| Ана күңеле балада, | кояш җылысы. |
| Ана өчен баладан | әнкәм-бал. |
| Ялгыша белдең | төзәтә дә бел |
| Ата-ананы тыңлаган - адәм булган, | тыңламаган - әрәм булган |
| Яктылык – кояш янында, яхшылык –ана янында | |

**-Әсәрнең <u>жанрын</u> билгеләп карыйк әле ?**

-Әкият.

**- Ни өчен әкият дип уйлыйсыз? Ә тормышта балалар белән мондый хәл булырга мөмкинме?**

-Әйе

- Димәк, язучы аны тормыштан алып язган. Әкият нигезендә тормыш тәҗрибәсеннән туган өмет – хыяллар чагылган уйдырма ята, ялкаулык, алдашу, көнчелек кире кагыла, гаепләнә.

**-Фикерләребезне гомумиләштереп, әкиятнең <u>темасын</u> билгелик. Язучының безгә әйтергә телгәгән фикерен ачыклыйк.**

- Әниләрне тыңларга, хөрмәт итәргә, аларга ярдәм итәргә кирәк.

Әниләргә карата шәфкатьле булырга кирәклеген әйтә ул. Малайлар әниләренә һәрвакыт терәк булырга тиешләр. Авыр вакытта әниләр үзләренең улларына таяналар. Яман эшләр

кылмаска, ялган сөйләмәскә.

**Бу әсәр белән автор нәрсә әйтергә теләгән? Әсәрнең <u>идеясен</u> билгелибез.** (төркемнәр фикер алыша)

- Начар эш эшләсәң, барыбер беленә.
- Алдашу – начар гадәт.

Беркемгә дә начарлык эшләргә ярамый

Әйе,татар халкында “Кырын эш кырык елдан соң да беленә”, - дигән әйтем дә бар.

- **Сабак алган әлеге малай, киләчәктә нинди кеше булыр дип уйлыйсыз?**

**VI. Рефлексия**

**- Автор кояшны кем белән чагыштыра?**

- Кояшны әни белән чагыштыра. Әни безгә ничек кирәк, җир йөзенә кояш та шулай кирәк. Нәтиҗә: димәк, кояш та, әни дә бер генә. Шуңа күрә әниләр - безнең өчен иң кадерле кешеләр. Әйе, балалар, әти-әниләрнең сүзләрен тыңлыйк, хәтерләрен калдырмыйк. Аларга кояш гомере телик. Укучылар, әти-әниегезнең, укытучыларның, олыларның сүзен тыңлагыз. Киң күңелле, мәрхәмәтле булыгыз.

Ә хәзер парталардагы сары кәгазь битләрен алабыз һәм үзебезнең яраткан әниебезгә теләк язабыз.

(бөтен укучы да яза һәм тактага беркетелгән сары түгәрәк янына чыгып беркетә)

Шул вакытта Габдулла Рәхимкулов башкаруында Фәтхерахман Әхмәдиев көенә Гөлшат Зәйнашева сүзләренә язылган “Җырлыйм әнием турында” дигән җырны тыңлыйк. .

**VII. Үзбәя**

“5” ле- дәрестә актив катнаштым һәм әсәрне тулысынча аңладым , дустыма да аңлата алам

“4” ле билгесе- әсәрдә әйтелгән фикерне аңладым, ләкин әле сорауларым калды дип уйлаган

“3” ле билгесе - миңа дәреснең темасын аңлавы авыр булды, шактый гына сорауларым калды дип уйлаучылар кызыл төстәге фишка ала.

**VIII. Өй эше**

1.“Һәрвакыт булсын әни” дигән темага кечкенә күләмле сочинение язарга.

2. Әниләр турында мәкальләр язып килергә.

## РАСЧЕТ СОПРОТИВЛЕНИЯ ПРОВОДНИКА.УДЕЛЬНОЕ СОПРОТИВЛЕНИЕ

*Гайфулина Ляйсана Зиннуровна,*
*МБОУ «СОШ № 3 города Мамадыш»*
*Мамадышский район*

**Цели:**

Ознакомить учащихся с электрическим сопротивлением проводников как физической величиной, дать объяснение природе электрического сопротивления и показать зависимость сопротивления от геометрических размеров проводника

**Задачи:**

*Образовательные:*

- формирования понятия удельного сопротивления вещества
- умение применять полученные знания при решении задач
-способствовать усвоению учащимися новых знаний о сопротивлении проводника,
-показать зависимость сопротивления проводника от длины , площади поперечного сечения и материала проводника

*Развивающие:*

- развитие умения наблюдать и выдвигать гипотезы при решении поставленных вопросов

- развития способов мыслительной деятельности (анализ, обобщение)

- развития речи (владение физическими понятиями, терминами)

- развития познавательного интереса учащихся;

*Воспитательные:*

- формирования научного мировоззрения

-воспитание устойчивого интереса к предмету

-положительного отношения к знаниям.

**Планируемые результаты**

*Личностные:*

-воспитывать уважение к интеллектуальному труду

-воспитывать уважение к физической науке как элементу человеческой культуры

- развитие доброжелательности и эмоционально-нравственной отзывчивости

-осознание смысла своей деятельности на всех этапах урока

-активизация волевых усилий в процессе урока

-воспитывать интерес к предмету через показ связи изучаемого материала с реальной жизнью

**Метапредметные:**

*Познавательные:*

-прогнозирование результата при наблюдении эксперимента

- контроль и корректирование своих действий при работе по заданному алгоритму

*Регулятивные:*

-высказывание результатов своих наблюдений

-участие в обсуждении проблем

-контроль и коррекция действий товарищей

*Коммуникативные:*

-выделение причин и следствий в наблюдаемых явлениях

-построение логической цепочки размышлений

-отбор аналогичных явлений из опыта своей повседневной жизни

*Предметные:*

-знание формулы для расчета сопротивления проводника

-умение решать качественные, расчетные и экспериментальные задачи по теме( как прямые так обратные)

-формирование навыков учебной работы

- умения делать выводы и устанавливать причинно – следственные связи по результатам наблюдений эксперимента.

Ресурсы.

Компьютер с выходом Internet; мультимедийные устройства( проектор , интерактивная доска); карточки раздаточного материала.

Ученики садятся группами и каждой группе раздаются карточки № 1,2,3,4 и каждому ученику карточка №5

Карточка №1

Соберите цепь по схеме. Измерьте напряжение при силе тока 0,5а и 0,6 А и вычислите в каждом случае сопротивление по закону Ома для участка цепи.

Карточка №2.

Соберите цепь по схеме. Измерьте напряжение и силу тока с никелиновыми проводниками одинакового поперечного сечения разной длины. Вычислите сопротивление обоих проводников.

Карточка №3.

Соберите цепь по схеме. Измерьте напряжение и силу тока с никелиновыми проводниками одинаковой длины, но разным поперечным сечением. Вычислите сопротивление обоих проводников.

Карточка №4.

Соберите цепь по схеме. Измерьте напряжение и силу тока с проводниками одинакового поперечного сечения и одинаковой длины никелиновым и нихромовым проводниками. Вычислите сопротивление обоих проводников.

Карточка №5

| до | Зависимость сопротивления | после |
|---|---|---|
| | Зависит ли сопротивление от длины | |
| | Зависит ли сопротивление от напряжения | |
| | Зависит ли сопротивление от площади поперечного сечения | |
| | Зависит ли сопротивление от силы тока | |
| | Зависит ли сопротивление от | |

Карточка № 6

№1. Рассчитайте длину железной проволоки, из которой изготовлен резистор, если ее толщина 0,05 $мм^2$. Удельное сопротивление железа - 0,1 Ом•$мм^2$/м.

№2. Рассчитайте площадь поперечного сечения никелиновой проволоки, из которой изготовлен резистор, если ее длина 1,2 м. Удельное сопротивление

| Этапы урока | Содержание действия учителя | Содержание действия ученика | Формируемые способы деятельности |
|---|---|---|---|
| Актуализация знаний | Сформулируйте закон Ома. Напишите формулу закона Ома. Сила тока, напряжение и сопротивление. В чем причина сопротивление? | Сила тока в участке цепи прямо пропорциональна напряжению на концах этого участка и обратно пропорциональна его сопротивлению. $I = U/R$ Сила тока, напряжение и сопротивление. Электроны взаимодействуют с ионами кристаллической решетки металла. | Подбор аргументов для доказательства своей позиции, формулирование выводов. |
| | Брем карточку № 5 и под словом до если вы думаете что зависит ставьте +, если думаете не зависит ставьте - | Ученики работают с карточкой № 5 | |
| Изучение нового материала | Каждой группе выдает карточки. | Ученики проделывают опыт и вычисляют сопротивление. | |
| | Каждая группа выходит к доске и пишет свой результат | Ученики делают выводы: 1 группа: карточка №1 | Умение работать по |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | Сопротивление не зависит от напряжения и силы тока.<br>2 группа: карточка №2 Сопротивление зависит от дины, чем больше длина тем больше сопротивление.<br>3 группа: карточка №3 Сопротивление зависит от площади поперечного сечения, чем толще проводник тем меньше сопротивление.<br>4 группа: карточка №4 Сопротивление зависит от рода проводника | заданному алгоритму, доказывать правильность решение с помощью аргументов. |
| | Подумайте, а как будем записывать формулу | Учащиеся говорят длина буквой l, площадь –S, удельное сопротивление - þ , тогда получаем формулу $R = \square \frac{l}{S}$. Делают записи в тетрадях. | Участие в диалоге, воспроизведение информации с заданной степенью свернутости. |
| | Сопротивление прямо пропорционально ______________ , обратно пропорционально _____________ и зависит от проводника.<br>R=PL/S где P- коэффициент, характеризующий электрические свойства вещества из которого изготовлен проводник . Этот коэффициент называется удельным сопротивлением вещества, L -длина проводника, L -м,<br>S- площадь поперечного сечения проводника , S - м<br>P=RS/L P-Ом*м ,но удобнее выражать Ом*мм/м ,а почему??? | Ученики вставляют слова длине площади.<br>Так как площадь поперечного сечения проводника очень маленькая величина.<br><br>Удельное сопротивление равно сопротивлению проводника из данного материала длиной 1 метр и площадью поперечного сечения 1 мм | Восприятие устной речи, проведение информационно-смыслового анализа текста. |
| Первичное закрепление | На доске написаны слова | Ученики прикрепляют эти слова. Делают вывод | Участие в диалоге, |

| | | | |
|---|---|---|---|
| нового материала | зависит и не зависит , а на столе лежат надписи длина, площадь, напряжение, сила тока, род вещества. Вы должны под словами зависит и не зависит прикрепить эти слова | сопротивление проводника зависит от длины, площади поперечного сечения и рода вещества | воспроизведение информации с заданной степенью свернутости. |
| | Сейчас берем карточки № 5 под словом после ставим + или -.у вас поменялось мнение или нет. | Ученики работают с карточкой №5 | Применять знания для решения задач |
| | Работа с таблицей. Откройте учебник на странице 105 Таблицу 8 Найдём в таблице: Удельное сопротивление меди равно 0,017 Ом•мм$^2$/м, это значит, что сопротивление проводника из меди длиной 1 метр и площадью поперечного сечения 1 мм$^2$ равна 0,017 Ом. Удельное сопротивление нихрома равно 1,1Ом*мм/м .Что это означает? Табличные данные приведены при 20°. Оказывается, удельное сопротивление увеличивается при повышении температуры. С чем связано увеличение удельного сопротивления при увеличении температуры проводника? | | |
| Коррекция знаний. | раздает карточку № 3 и говорит задание решить : используя | Ученики самостоятельно решают задачи и проверяют по слайду | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | новую формулу, рассчитать l или S и проверяем свои решение по слайду | | |
| Рефлексия | Что нового вы узнали на уроке? Что было наиболее трудным, интересным? Достигли ли вы цели? Оценки за урок. | Пишут ответы на вопросы | Выполнять задания по своим силам и знаниям |
| Домашнее задание | §45, учебника; вопросы, упр. 20(2а,3) или упр. 20 (1,2б) письменно. | | |

*Список использованной литературы*

1.Пёрышкин А.В. Физика. 8 класс.: Учебник для общеобразовательных учебных заведений[Текст]/ А.В. Пёрышкин. – М.: Дрофа, 2017.
2.Лукашик В.И. Сборник задач по физике для 7-9 классов общеобразовательных учреждений [Текст]/ В.И. Лукашик, Е.В. Иванова.- М.: Просвещение, 2002.

## ПРОГРАММА ВНЕУРОЧНОЙ ДЕЯТЕЛЬНОСТИ «НАСЛЕДИЕ ТАТАРСТАНА»

*Гарипова Айгуль Котдусовна,*
*училель начальных классов*
*МБОУ "Гимназия №1 имени*
*Ч.Т.Айтматова п.г.т.Кукмор" Кукморского*
*муниципального района РТ*

**Пояснительная записка**

В соответствии с ФГОС, разработанном с учетом региональных, национальных и этнокультурных потребностей народов РФ, идея сохранения и развития нашей страны является приоритетной в современном образовании.

В целях обеспечения интересов младших школьников в Республике Татарстан разработано учебное пособие «Наследие Татарстана». В основу реализации поставленной цели положен принцип интеграции этнорегионального компонента в содержании предметных областей начального образования и внеурочной деятельности.

Содержание курса направлено на достижение следующих результатов:

-формирование уважительного отношения к семье, родному городу и селу, Республике Татарстан, истории, культуре родного края, его современной жизни;

-понимание ценности, целостности и многообразия окружающего мира, своего места в нем;

-воспитание чувства гордости за национальные свержения, открытия, победы;

-освоение доступных способов изучения окружающего мира(наблюдения, запись, сравнение, классификация и др.),получении информации из семейных архивов, от окружающих людей, в открытом информационном пространстве.

## Актуальность программы

Во-первых, в настоящее время остро ощущается необходимость возрождения духовности, изучения культуры своего народа и народов, проживающих рядом, изучения прошлого и настоящего своей «малой родины», восстановление духовности для формирования нравственной личности гражданина и патриота своей страны.

Во-вторых, обострение межэтнических отношений, сложность и неоднозначность этнокультурных процессов, происходящих в обществе, стимулируют интерес учащихся к истории народов, живущих на территории региона, к познанию их истоков и корней.

В-третьих, Конституция Российской Федерации гласит: «Мы, многонациональный народ Российской Федерации, соединённый общей судьбой …» На территории Республики Татарстан проживают представители многих национальностей. Именно в школе должна быть сосредоточена не только интеллектуальная, нои гражданская, духовная и культурная жизнь школьника. Ребёнок школьного возраста наиболее восприимчив к эмоционально-ценностному, духовно-нравственному развитию, гражданскому воспитанию. В то же время недостатки развития и воспитания в этот период жизни трудно восполнить в последующие годы. Пережитое и усвоенное в детстве отличается большой психологической устойчивостью.

**Цель программы:** пробуждение у обучающихся живого интереса к изучению культуры народов Поволжья, формирование человека патриота, отличающегося высокой нравственностью, толерантностью.

**Задачи программы:**

1. Изучение обычаев,традиций и духовной культуры народов, проживающих в Татарстане.
2. Формирование и сохранение семейных ценностей и традиций.
3. Активизация поисковой деятельности учащихся.
4. Принятие культуры и духовных традиций многонационального народа Российской Федерации.
5. Воспитание чувства гордости за свой многонациональный народ, его культурное наследие.

**Принципами отбора содержания материала программы являются:**

- системность;
- научность;
- доступность;
- возможность практического применения полученных знаний;
- реалистичность, с точки зрения возможности усвоения основного содержания программы .

Данный курс дает учащимся сведения практического характера, знакомит их с культурным наследием Татарстана. Необходимым условием реализации этих целей и задач является использование в ходе проведения занятий новых активных форм работы наряду с традиционными.

**Методы обучения:** Объяснительно-иллюстративный, частично-поисковый, исследовательский.

**Формы обучения:** фронтальная, групповая, парная, индивидуальная.

**Прогнозируемые результаты**

- Готовность к социальному и профессиональному самоопределению учащихся
- Сформированные знания о русских , татарских, чувашских народных традициях, основных достижениях культуры этих народов;
- Развитые навыки культурного поведения и нравственного отношения к себе и другим людям в учебной и внеучебной деятельности;
- Сформированное национальное сознание и толерантное отношение к русской культуре и культурам других народов.

**Учащиеся должны знать:**

• Историю родного края, его традиции, обычаи и обряды

• Характеристику различных профессий, связанных с народными промыслами

**Учащиеся должны уметь:**

• Изготавливать декоративно – прикладные изделия, служащие для оформления быта, интерьера, одежды

• Изготавливать традиционные блюда татарской народной кухни

• Изготавливать яркие оригинальные сувениры и подарки

• Составлять компьютерную презентацию и выступать публично

• Взаимодействовать в коллективе

Структурной особенностью программы является модульно – тематическое планирование содержания занятий.

**Календарно- тематическое планирование 1 класс**

| | Тема занятия | Кол-во часов | План | Факт |
|---|---|---|---|---|
| | **Моя Республика** | | | |
| | Татарстан-наша малая родина | 2 | | |
| | Казань-столица Татарстана | 1 | | |
| | Народы Татарстана | 2 | | |
| | **Я и мой мир** | | | |
| | Что такое музыка? | 1 | | |
| | Музыка моего народа | 1 | | |
| | Природа в творчестве человека | 1 | | |
| | Человек-творец культуры | 1 | | |
| | Как мы общаемся с миром | 2 | | |
| | Путешествие в страну поэзии Тукая | 2 | | |
| | **Мой класс** | | | |
| 0 | Книга-наш друг и наставник | 1 | | |
| 1 | Делу-время | 1 | | |
| 2 | Потехе-час | 1 | | |
| | **Мой дом и семья** | | | |
| 3 | Моя семья | 1 | | |
| 4 | Мы-одна семья | 1 | | |
| 5 | Хлеб-всему голова | 1 | | |
| 6 | Бабушкины сказки | 2 | | |
| | **Город и село** | | | |
| 7 | Мой любимый город | 1 | | |
| 8 | Города нашей республики | 2 | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 9 | Родное село | 2 | | |
| 0 | Пойдем в музей | 1 | | |
| 1 | Мы помним наших героев | 2 | | |
| 2 | Знаменитые люди | 1 | | |
| | **Я и окружающий мир** | | | |
| 3 | Я-часть мира | 2 | | |
| 4 | Обобщающее занятие | 1 | | |
| | Итого-33ч | | | |

**Календарно- тематическое планирование 2 класс**

| | Тема занятия | Кол-во часов | План | Факт |
|---|---|---|---|---|
| | **1 раздел** ***Наш дом- Татарстан*** | | | |
| | Наш дом-Татарстан | 2 | | |
| | Все мы-жители Земли | 1 | | |
| | Время | 1 | | |
| | Древний календарь | 1 | | |
| | Календарь примет | 1 | | |
| | **2 раздел** ***Времена года*** | | | |
| | Времена года | 1 | | |
| | Осень-прекрасная пора. Осень в творчестве | 1 | | |
| | Осень в творчестве | 1 | | |
| | Осенние праздники и обряды народов Татарстана | 2 | | |
| 0 | Зима-красавица | 2 | | |
| 1 | Мир освещается солнцем, а человек-знанием | 2 | | |
| 2 | Зима- пора сказок | 2 | | |
| 3 | Зимние праздники и обряды народов Татарстана | 2 | | |
| 4 | Народные ремесла и промыслы | 1 | | |
| 5 | Будь здоров! (Зимние игры) | 2 | | |
| 6 | Пришла весна-отворяй ворота | 1 | | |
| 7 | Весенние праздники и обряды народов Татарстана | 1 | | |
| | Мы любим лето | 1 | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 8 | | | | |
| 9 | Будь здоров!(Весенние и летние игры) | 2 | | |
| 0 | Летние праздники и обряды народов Татарстана | 2 | | |
| 1 | Экология Татарстана | 1 | | |
| 2 | Красная книга Татарстана | 1 | | |
| 3 | Заповедные места нашей республики | 1 | | |
| 4 | Казанский зоопарк | 1 | | |
| 5 | Обобщающее занятие | 1 | | |
| | Итого-34ч | | | |

**Календарно- тематическое планирование 3 класс**

| | Темы занятия | Кол-во часов | План | Факт |
|---|---|---|---|---|
| | **Радость познания** | | | |
| | Мир освещается солнцем, а человек-знанием | 1 | | |
| | Одна книга тысячи людей учит | 1 | | |
| | Экскурсии в музей | 1 | | |
| | Экскурсии по Казани | 1 | | |
| | Путешествуем по республике | 2 | | |
| | Казань-город туристов | 1 | | |
| | Татарстан-наш общий дом | 2 | | |
| | Россия-наша большая Родина! | 2 | | |
| | Татары живут во всем мире | 2 | | |
| 0 | Знание языков открывает окно в мир | 1 | | |
| 1 | Транспорт в Татарстане | 1 | | |
| 2 | Средства информации и связи | 2 | | |
| | **Мир как дом** | | | |
| 3 | Мир природы в народном творчестве | 1 | | |
| 4 | Природные стихии в народном творчестве | 1 | | |
| 5 | Земля и растения в народном творчестве | 1 | | |
| 6 | Образы животных в народном творчестве | 1 | | |
| | **Дом как мир** | | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 7 | У кого есть дом, у того и страна есть | 1 | | |
| 8 | Мой дом | 2 | | |
| 9 | Приходите в гости | 1 | | |
| 0 | Человек без родни не живет | 1 | | |
| 1 | Моя родословная | 2 | | |
| 2 | Муж и жена-одна душа | 1 | | |
| 3 | Родители и дети | 1 | | |
| | **В поисках Всемирного наследия** | | | |
| 4 | Казанский Кремль-сердце столицы нашей республики | 1 | | |
| 5 | Болгар-столица древнего государства | 1 | | |
| 6 | Духовные сокровища Татарстана | 1 | | |
| 7 | Обобщающее занятие | 1 | | |
| | Итого-34ч | | | |

*Список использованной литературы*


1. *М.М.Гибатдинов, Л.Р.Муртазина.* "Наследие Татарстана", Татарское детское издательство, 2016
2. *Айрат Арсланов.* Студия "Гульзада". "Шанлы Казан".
3. *Ренат Бикбулатов.* Казань – Знаменитые люди. Книга первая. Издательство "Заман" 2003.
4. *М. А. Валиуллин.* Балачак илендә Казань – 2009.
5. *Л.И. Минхазева.* Татар балалар әдәбияты. Казан: ТО "Хәтер" нәшрияты, 2003.
6. *К.Р.Синицына.* История Татарстана и татарского народа. XVI – XVIII вв. Казань Издательство "Магариф"2000.
7. *Ф. Хузин.* "Средневековая Казань". Татарское книжное издательство, 2004.
8. *Л.А.Харисова.* "Культура народов Татарстана". Издательство "Магариф", 2005.
9. *Р.Яхин.* Фоноуроки. РТ НТП "Школьник".
10. Путешествие по столице Татарстана. Редакционно-издательский центр "Титул" К 2002.
11. Татар халык ашлары. Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1987.
12. Татар халык авыз иҗаты. Мәкальләр һәм әйтемнәр. Казань. Татарское книжное издательство, 1987.
13. Татар халык авыз иҗаты. Риваятьләр һәм легендалар. Казань. Татарское книжное издательство, 1987.
14. MP3 диск "Кайт, карлыгач." Ильяс Гыйләҗетдин, Резеда Валиева. Мәктәп укучылары өчен иң популяр җырлар.

Журналы "Сөембикә", "Ялкын", "Салават күпере".

# “БАЛЫК БИСТӘСЕ... ШУШЫ ЯКТАН, ШУШЫ ТУФРАКТАН БЕЗ...”

*Гарипова Зөлфирә Зөлфәт кызы,*
*Балык Бистәсе муниципаль районы*
*Урахча төп гомуми белем мәктәбенең*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

Үз халкыңның тарихы, ата-бабаларның тормышы беркемне дә битараф калдыра алмый. Балык Бистәсендә шигырь язучылар кайбер башка төбәкләргә караганда нигә күбрәк туа икән? Бәлки - Балык Бистәсе моңлы яктыр. Шулай ук биредәге табигатьнең төрлелеге - урманнары, Чулман буендагы киң болыннары, су баса торган үзәннәрдәге бихисап күлләре дә шигърияткә килүдә зур этәргеч булып торадыр, һәрхәлдә, миңа шулай тоела. Ни өчен дигәндә, Балык Бистәсенең су юлында сөенечләр көенечләр белән очрашкан. Ак пароходлар, җитез метеорлар әткәй- әнкәйләрдән, сөйгән ярлардан аерып, әле Казанга, әле Түбән Кама белән Чаллы ягына алып киткәннәр. Мөгаен, бу якларда җан тетрәтердәй аерылу җырлары да мулрак сибелгәндер. Борынгыдан ук ярсу рухлы, эшчән, егәрле бабайлар яшәгән як бит бу, Казан яулап алынгач та, озак тартышкан, баш бирмәгән төбәк бит бу!Шундый халык яшәгән урында җыр туа, шигырь туа, шагыйрь - язучылар туа. Равил Фәйзуллин, Вакыйф Нуруллин, Кадыйр Сибгатуллин, Әхәт Сафиуллин, Сәет Шәкуров, Роберт Әхмәтҗанов, Әхәт, Рәкыйп, Ринат Гаффарлар кебекләр туа. Алар юкка гына әдәбият-сәнгатькә гашыйк булып үсмәгәннәрдер. Туган җир... Безнең һәрберебезнең газиз туган йорты, йортыбыз урнашкан кадерле туган авылыбыз бар. Һәр авылның үзенә генә хас, кабатланмас, истә кала торган урыннары бар. Туган ягыбызның кырлары, басулары, шаулап торган урманнары җаннарыбызга рәхәтлек биреп, туган илгә мәхәббәт тәрбияли. Чулман дулкыннары шаулавы, Арыш урманнарындагы моңлы кошлар сайравы, татар гармуннарының үзәк өзәрдәй авазлары кушылып, бу моңны тагын да баеталар. Үзе җыр булып еракларга агып ягучы Чулман елгасының биек ярларына утырган адәм, тәнендә җаны булса, я җырлап җибәрер, я каләмгә тотыныр... Бу як кешеләренә аерым бер кызыксыну һәм ярату белән карыйм мин. Шуңа күрә дә , авторлык программам аларның бай иҗади мирасына багышлана.

Хәзерге чорда фәннәрне укыту эчтәлеген регионлаштыру, ягъни әйләнә тирәбездәге чынбарлыкка бәйләү, тәрбия процессын яңартуның бер юнәлеше булып тора. Педагогик әдәбиятта ул милли-региональ компонент термины белән йөртелә. Укучы үзе яшәгән төбәкне яратсын, аның мәдәни, тарихи кыйммәтләре турында уйлап фикер әйтә алсын өчен, укыту процессында моңа өйрәтергә кирәк.

Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының “Мәгариф турында”гы Законнары, аларның үтәлүен тәэмин итү программалары укыту-тәрбия процессына милли-региональ компонент кертүнең хокукый нигезе булып тора.

Төп гомуми белем бирү мәктәбендә татар әдәбиятын укыту программасы дәүләт стандарты нормаларыннан чыгып төзелә. Анда күзалланган белемне укучыларга җиткерү, аларда эстетик кануннарга нигезләнеп фикер йөртү һәм хис итү культурасы булдыру, милли үзаң тәрбияләү, сәнгати бәя бирергә өйрәтү. Укытучыдан тирән белем, мөстәкыйль фикер йөртү сәләте булуны, эшкә иҗади якын килүне таләп итә. Әмма укучыларны туган якта туып үскән каләм ияләренең иҗаты белән таныштырмый торып, әдәбияттан үзләштерергә тиешле белемне тулысынча алалар дип әйтеп булмый. Укучы мәктәп чорында һәр предметтан үз төбәге буенча мәгълүмат алып, нәни ватанының патриоты булып үсәргә тиеш.

Курс өйрәнгәндә укучылар тарафыннан интельлектуаль һәм эмоциональ эшчәнлек төрләре файдаланыла. Мәсәлән, теманы тикшергәндә укучылар татар әдәбияты дәресләрендә алган белемнәрен файдаланалар, шул ук вакытта белемнәрен тирәнәйтәләр һәм яңа белемнәр алалар. Алган белемнәрен практик дәресләрдә иҗади файдалану укучыларга әхлакый канәгатьлек бирә, алга таба предметны өйрәнүгә кызыксыну уята һәм эмоциональ кәеф булдыра.

Укучыларның шәхси эшчәнлегенә күбрәк игътибар бирергә киңәш ителә. Укучылар лекция-практик дәресләрдә билгеле бер күләмдә белем алалар һәм биремнәрне үзләре мөстәкыйль башкаралар, ә аннары күмәк рәвештә фикер алышалар. Парлы һәм группалы эш алымнары куллану да уңай нәтиҗә бирә. Дискуссияләр, сораулар, җаваплар, кыска комментарияләр, аннотацияләр дәресләрне төрләндерәләр, кызыклырак итәләр.

**Программаның структурасы.**

Программа өч өлештән тора: аңлатма язуыннан, төп бүлекләрне, белем һәм күнекмәләрне үз эченә алган программаның эчтәлегеннән, укучыларның әзерлек дәрәҗәсенә таләпләреннән.

**Бу программаның максаты:** туган якны, туган нигезне, төбәкне – Балык Бистәсе төбәген, аның табигатен, халкын, аның үткәнен, хәзергесен, халкыбыз һөнәрләрен, иҗатын өйрәнү аша укучыларны рухи яктан бай, иҗади сәләтле, югары мәдәниятле, камил шәхес итеп тәрбияләү.

**Программа әдәбият укытуда түбәндәге бурычларны хәл итәргә ярдәм итә:**

1. Балык Бистәсе төбәгендә һәм Балык Бистәсеннән читтә яшәп, ләкин безнең төбәктән булган иҗат итүче һәр язучы, шагыйрьнең иҗаты белән таныштырырга, аларның иҗаты турында гомумиләштерелгән фикер әйтә белергә өйрәтергә.
2. Укучыларның сөйләм телен, фикерләү сәләтен үстерү, аларны фәнни һәм иҗади эзләнү эшенә җәлеп итү, Балык Бистәсеннән чыккан журналистлар иҗатына таянып, журналистика өлкәсе белән кызыксыну уяту.
3. Якташ язучылар иҗатының гомумтатар әдәбияты тарихында тоткан урынын билгеләү.
4. Туган якка мәхәббәт тәрбияләү.
5. Балаларның иҗат активлыгын көчәйтергә этәргеч бирү- милли үзаң тәрбияләү.

**Курсның юнәлеше:**

-Балаларның эстетик зәвыгын, иҗади фантазияләрен үстерү.

-Балаларны якташ язучыларыбыз иҗатларына нигезләнеп үзара аралашу культурасына өйрәтү.

-Балаларның милли телен баету.

-Сәләтле балаларны ачыклау.

**Программаның билгеләнеше:**

Электив курс программасы киләчәктә һөнәрләрен филология өлкәсе (татар теле һәм әдәбияты укьтучысы, журналист, фән эшлеклесе, язучы, шагыйрь) белән бәйләүче гуманитар юнәлешле профиль классларда белем алучы 8-9 сыйныф укучыларына адреслана.

**“Балык Бистәсе..**

**Шушы яктан, шушы туфрактан без!”**

***электив*** курсы белем биреп кенә калмый, ә мөстәкыйль эшчәнлек күнекмәләрен булдырырга һәм һәр баланың шәхси мөмкинлекләрен ачарга ярдәм итә.

Электив курсның эчтәлеге турыдан-туры мәктәптә татар әдәбиятын укыту буенча төп курс программасына өстәмә буларак тәкъдим ителә.

Туган төбәге белән кызыксынган, матур әдәбият әсәрләрен укырга яраткан укучыларга түгәрәк эше планы буларак та тәкъдим итәргә мөмкин.

**Укучыларның әзерлек дәрәҗәсенә таләпләр:**

сүз сәнгатенең образлы табигате;

өйрәнгән әдәби әсәрнең (шигырьнең)эчтәлеге;
Якташ язучыларыбызның тормыш һәм иҗат юлларының төп факторлары;
әдәби текстны кабул итү һәм анализлау;
әдәби текстның мәгънәви өлешләрен аерып чыгару, укыган буенча тезислар һәм план төзү;
әдәби әсәрнең төрен һәм жанрын ачыклау;
укыган әсәрнең темасын, проблемасын, идеясын ачыклау;
геройларга характеристика бирү;
сюжет, композиция үзенчәлекләрен, махсус сурәтләү чараларының ролен ачу;
әдәби әсәрдәге эпизодларны һәм геройларны чагыштыру;
автор позициясен ачыклау;
укыганга үзеңнең мөнәсәбәтеңне белдерү;
әсәрне (шигырьне) сәнгатьле итеп уку;
кабатлап сөйләүнең төрләреннән файдалану;
өйрәнелгән әсәргә бәйле телдән һәм язмача фикерне белдерү;
укыган әсәр буенча фикер алышуда катнашу, фикерләреңне дәлилли белү;
укыган әсәрләргә бәяләмә (отзыв) язу;
татар әдәби теленең нормаларына нигезләнеп, кирәкле темага телдән һәм язмача бәйләнешле текст төзү;
эстетик зәвыкка туры килә торган әдәби әсәрләрне сайлау һәм аларны бәяләү;
аерым автор, аның әсәре, гомумән әдәбият турында кирәкле белешмә әдәбият, вакытлы матбуга, Интернет чаралары һ.б. аша эзләү.

**Көтелгән белем нәтиҗәләре:**

1.Якташларыбыз турында мәгълүмат алу.
2.Әдәби әсәрләрне анализлый белү.
3.Дискуссияләрдә катнашу, үз фикереңне әйтү
4.Укучыларда милли үзаң формалашу, туган төбәктә намуслы хезмәт итү теләге уяту.
5.Үз халкыңның рухи байлыгын өйрәнү, аны үстерү һәм саклау өчен үзләреннән өлеш кертүгә омтылыш тәрбияләү.

***Календарь-тематик план***

| | Тема | әг | Үткәрү формасы | Өстәмә эш |
|---|---|---|---|---|
| . | **1нче бүлек** Балык Бистәм-туган ягым | | әңгәмә, лекция | сочинение |
| . | Районыбыз тарихы | | әңгәмә, лекция | Район тарихына караган материаллар туплау |
| | Районыбызның туган як музеена сәяхәт | | Сәяхәт-дәрес | Иҗади эш “Туган ягымның киләчәге” |
| | Балык Бистәсе төбәгенең гореф-гадәтләре һәм әби-бабаларыбызның йолалары | | Эзләнү-тикшеренү эше | Иҗади эш.Гаиләбезнең буыннан-буынга килгән традицияләре |
| | “Җиде бабаңны беләсеңме?” Шәҗәрәләр төзү | | Гамәли эш | Шәҗәрәләр төзү |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Туган ягыбызда тел үзенчәлекләре | | Эзләнү-тикшеренү эше | Туган ягыбызда тел үзенчәлекләрен өйрәнү |
| | Район матбугаты тарихы. ”Авыл офыклары” газетасы үсеше | | Редакциягә сәяхәт | Вакытлы матбугатка күзәтү,төбәгебездән чыккан кешеләрнең язмалары белән танышу |
| | Районыбыздан чыккан күренекле кешеләр (һөнәр ияләре, хезмәт алдынгылары) | | Әңгәмә, күзәтү | Реферат язырга |
| | **2нче бүлек** Данлыклы шәхесләребез. Районнан чыккан язучылар һәм сәнгать әһелләре белән таныштыру | | Лекция,күзәтү | Презентация ясарга |
| 0 | **2.1 Язучы,шагыйрьләр** “Тургай тәрәзәсе”китабы авторы – Р.Әхмәтҗанов иҗаты | | Лекция,сәнгатьле уку,әңгәмә | Ошаган шигырьләрне ятларга |
| 1 | Мәңге яшисе килә... Фәтхерахман Әхмәдиев | | Лекция, сәнгатьле уку, әңгәмә | Шигырьләрен укырга |
| 2 | Зәйнәп Бәширова | | Лекция, сәнгатьле уку,әңгәмә | Шигырь язарга |
| 3 | Әхәт Гаффар | | Лекция, күзәтү әңгәмә | Шигырьләрен укырга,ятларга |
| 4 | Рәсимә Гарифуллина | | Лекция, күзәтү әңгәмә | Шигырьләре буенча фикер алышу |
| 5 | Вакыйф Нуруллин | | Лекция, сәнгатьле уку, әңгәмә | Китап укучылар конференциясе |
| 6 | Әхәт Сафиуллин | | Лекция, күзәтү әңгәмә | Китап укучылар конференциясе |
| 7 | Миннур Сафиуллин. “Балан тәлгәшләре” җыентыгы белән танышу. | | Лекция, сәнгатьле уку, әңгәмә | Шигырьләрен укырга,ятларга |
| 8 | Кадыйр Сибгатуллин | | Лекция, сәнгатьле уку,әңгәмә | Шигырьләрен укырга |
| 9 | Миргазиз Укмасый | | Лекция, сәнгатьле уку, әңгәмә | Шигырьләрен укырга |
| 0 | Вазыйх Фатыйхов белән очрашу.Иҗаты белән танышу. | | Очрашу,әңгәмә | “Бер йотым мәхәббәт”дискын тыңлау. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Равил Фәйзуллин | | Лекция, ,күзәтү, әңгәмә | Мәкаләләр бәйгесе |
| 2 | Мансур Шиһапов | | Әңгәмә, лекция, күзәтү | Презентация ясарга. |
| 3 | Гөлнур Әхмәдуллина-Архипова | | Әңгәмә, күзәтү | Бер шигырен анализларга. |
| 4 | **2.2 Артистлар** Рауза Хәйретдинова | | Әңгәмә, күзәтү | Театральләштерелгән күренеш әзерләү |
| 5 | Равил Шәрәфиев | | Әңгәмә, күзәтү | |
| 6 | Хәлим Җәләлов | | Әңгәмә, лекция, күзәтү | Материаллар тупларга |
| 7 | Зөфәр Билалов-Балык Бистәсе сандугачы | | Әңгәмә, күзәтү | Җырларын тупларга |
| 8 | Илназ Минвәлиев | | Лекция, күзәтү әңгәмә | Концертын карарга |
| 9 | Гүзәл Җәләлова | | Очрашу,әңгәмә | Материал тупларга |
| 0 | Венера Шәмиева Эльвира Хамматова | | Лекция, күзәтү әңгәмә | Җырларын тыңларга |
| 1 | **2.3 Журналистлар** Флёра Абдуллина | | Лекция, күзәтү әңгәмә | “Татарлар” тапшыруын карарга Фәнни эш - реферат язарга |
| 2 | Раиф Гыймадиев | | Лекция, күзәтү әңгәмә | “Җир сулышы” тапшыруын карарга |
| 3 | Идрис Аметов | | Лекция, ,күзәтү әңгәмә | “Минем яраткан журналистым”-хикәя язарга |
| 4 | Йомгаклау.Зачет-дәрес | | Зачет-дәрес | |

**Программаның эчтәлеге (34 сәгать).**

**Программа 2 зур бүлектан тора.**

**1 бүлек. Балык Бистәм – туган ягым!** (8 сәгать). Укучыларны районыбыз тарихы, туган як музее, Балык Бистәсе төбәгенең гореф-гадәтләре һәм әби-бабаларыбызның йолалары, район матбугаты тарихы. ”Авыл офыклары” газетасы үсеше, районыбыздан чыккан күренекле кешеләр (һөнәр ияләре, хезмәт алдынгылары) белән танышу.

**2 бүлек.Данлыклы шәхесләребез. (26 сәгать)**
Районнан чыккан язучылар һәм сәнгать әһелләре белән танышу.

**2.1. Язучы,шагыйрьләр.(14 сәгать)**
Якташларыбыз турында мәгълүмат туплау.
Әдәби әсәрләрне(шигырьләрне) анализлау.

**2.2 Артистлар.(7 сәгать).**
Спектакльләрдән өзекләр карап фикер алышу.

**2.3 Журналистлар.(4 сәгать)**

“Татарлар”, “Җир сулышы” тапшыруларын карап, журналистларыбыз иҗатына күзәтү ясау.

*Кулланылган әдәбият*

- Аметов И.Г. “ Алар сине зурлый. Балык Бистәсе”.-Казан:РИЦ “Школа”, 2007.
- “ Авыл офыклары” газетасы,2001- №60-70,2014- №14
- Әхмәдуллина-Архипова Г.К. “Ялгышу”:Повестьлар.-Казан: Яңалиф,2005.
- Әхмәдуллина-Архипова Г.К. “Син бар..”:Шигырьләр.-Казан: РИЦ “ Школа” 2008.
- Гәрәева Г.Х “ Без-Балык Бистәсеннән”-Казан:РИЦ”Школа”,2009.-248б
- Гарифуллина Р.А. “Бүген ярат!” Шигырьләр.-Казан:ДУП ПНК “Идел-пресс”, 2001.
- “Мәйдан” журналы №9, 2003 ел.
- Радуга над Камой. Сборник стихов.- Рыбная-Слобода, 2011
- Сафиуллин Ә.Х. “Йомгак очы”.Маҗаралы повесть.Казан: “ Дом печати” нәшрияты.-2002.112бит
- Сафиуллин Ә.Х. “Тормыш сукмаклары” Повестьлар,хикәяләр,эсселар.-Казан:Татар.кит.нәшр., “ Школа”,.
- Сафиуллин Ә.Х. “ Туган якның таң җилләре” . Шигырьләр, җырлар.- Казан: ГУП ПИК “Идел-Пресс” 2002.
- Солтан Ф.С. “ Баллы миләш”: шигырьләр, хикәяләр.-Казан: Татар.кит.нәшр.,2011
- Трофимова М.И. “ Рыбная Слобода. Живые голоса.(Популярные очерки об истории и людях Рыбной Слободы).- Казань, Идел-Пресс. 2006
Нәрсә ул музей? Музей һәм мәктәп. Музей активын сайлау һәм актив эшен оештыру. Музей эшчәнлегенең спецификасы һәм төп юнәлешләре белән танышу

Музей активы эшчәнлеген төркемнәргә бүлеп оештыру:

-эзләнү төркеме, лекторлар төркеме, экскурсоводлар төркеме, бизәүчеләр төркеме. Һәр төркемнең эшчәнлеге белән танышу.

Мәктәп музеена экскурсия: экспонатлар белән танышу; бизәлешне күзәтү һәм өйрәнү;

Башка музейлар эшчәнлеге белән виртуаль танышу. Музейның инвентарь китабын төзү һәм аның белән эшләү тәртибен күрсәтү . Музейдагы һәр экспонатны инвентарь китабына теркәү. Картотека. Һәр экспонатка картотека төзү.

**2. Районыбыз тарихы**

Арча төбәгенең табигате, географиясе. Арча төбәге символикасы. Районыбызның тарихи-мәдәни һәйкәлләре. Арча атамасы килеп чыгышы. Викторина “Арчаны беләсеңме?”

**3. Туган авылыбыз тарихы**

Түбән Мәтәскә, Югары Мәтәскә авыллары тарихы. Казиле, Мөндеш авыллары тарихы.

Без яшәгән урамнар тарихы. Урамнарның рәсми һәм җирле атамалары. Без яшәгән авылларның җирле атамалары. Елга-күлләре, чишмә-коелары.

Халкыбызның һөнәрләре. Игенчелек. Терлекчелек. Һөнәрчелек. Безнең авылларга гына хас һөнәрләр, аның вакытлар үтү белән үзгәрүе.

Туган ягыбызда мәгариф тарихы. Мәдрәсәләр тарихы. Беренче мәктәпләр. Мәктәпкәчә тәрбия учреждениеләре тарихы.

Авылның Бөек Ватан сугышы чоры тарихы. Сугыш һәм хезмәт ветераннары. Сугыш балалары кемнәр алар? Тыл ветераннары. Танылган тракторчы Рахманова Мөнирә. Авылыбызның тырыш хезмәтләре белән дан казанган кешеләре. Авылларыбызның иҗат кешеләре. Гайсә Гатауллин. Рәсих Шамский. Туган ягымның галимәләре. Ситдиков И.Б. Әхмәтова Эльмира. Шәяхмәтова Р.И. Танылган спортсменнар. Сабантуй батырлары.

**4. Гаилә тарихы – авылым тарихының бер өлеше**

Шәҗәрә – гаилә тарихы. Аны ничек төзергә. Минем гаиләм традицияләре. Гаилә реликвиясе. Кушаматлар килеп чыгу тарихы. Авыл кушаматлары.

**5. Районыбызның тарихи-мәдәни урыннары**

Арча шәһәренең Казан арты музее. Габдулла Тукай белән бәйле тарихи урыннар. Түбән Мәтәскә авылының тарихи-мәдәни урыннары. Казиле авылы мәчете һәм мәдрәсәсе.

**1. Теоретик эшләр.**

- музей эшчәнлеге, аның төп юнәлешләре белән танышу;
- музей активы, аның төркемнәре эшчәнлеге белән танышу;
- инвентарь китабы, картотека, этикетаж төзергә өйрәнү;

**2. Гамәли чаралар.**

- кичәләр, очрашулар үткәрү;
- тикшерү эшләре уздыру;
- экспозицияләр, экспонатлар туплау, якташларыбыз иҗатларын өйрәнү һәм җыю;
- укучылар иҗатын чагылдырган стендлар төзү;
- мәктәп музее сайтын тулыландыру;

**3. Экскурсия һәм походлар**

- районыбызның төрле музейларына һәм авылыбызның тарихи-табигый һәйкәлләренә экскурсияләр;
- башка музей хезмәткәрләренең һәм музей активының эшләү рәвеше, эш тәртибе белән танышу.

## Йомгаклау.

Үз авылыңны, аның тарихын, атаклы, дәрәҗәле шәхесләрен, халыкның гореф-гадәтләрен белү бик мөһим. “Илен белмәгән – игелексез, халкын белмәгән – холыксыз, нәселен белмәгән – нәсәпсез”, – дип халык юкка гына әйтмәгән.

Берничә ел рәттән музей эшчәнлеге, туган як тарихын өйрәнгәннән соң, программаның бик кирәк булуына инандым. Туган ягы белән кызыксынучы укучыларым артты.

Программаның иң отышлы якларыннан берсе – эзләнү-тикшеренү формасында оештырылган булуы. Төрле проектлар барлыкка килде: “Урам тарихы”, “Шәҗәрә – гаиләм көзгесе”, “Авыл: кичә һәм бүген” һ.б. Фәнни-гамәли конференциядә актив һәм нәтиҗәле катнашабыз.

Программаны үзләштергән укучылар туган илебезне нык яратырлар һәм сакларлар дип ышанасы килә.

## Кулланылган чыганаклар исемлеге


1. Дик Н.Е., Валишин Ю.И. Экспозиция школьного краеведческого музея.- /Н.Е.Дик, Ю.И.Валишин // М.: Просвещение.-2002.-№ 6
2. Соколова И.В. Следопыты ведут поиск.- /И.В.Соколова // М.: Просвещение.- 2009.-150с.
3. Татарстан Республикасының Арча районы хакимияте “Арча төбәге тарихы”, Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1996.
4. Фирдәүс Гарипова “Авыллар һәм калалар тарихыннан”, Казан, 1997.
5. Түбән Мәтәскә урта мәктәбе музее материаллары.
6. Арча районы Түбән Мәтәскә этнографик музее сайты. http://nmsosh.wixsite.com/meteskimuzei

# РОЛЬ ШКОЛЬНОГО КУКОЛЬНОГО ТЕАТРА НА АНГЛИЙСКОМ ЯЗЫКЕ В ФОРМИРОВАНИИ ЛИЧНОСТИ РЕБЕНКА

*Иванова Ландыш Радифовна,*
*учитель английского языка*
*МБОУ "Яныльская средняя школа" в с.Вахитово*
*Кукморского муниципального района*

Процесс модернизации содержания школьного образования предполагает организацию эффективного обучения иностранному языку в начальной школе, формирование иноязычной коммуникативной компетенции учащихся. Решению данной задачи способствует формирование интереса у детей к овладению иноязычной культурой посредством создания благоприятных условий для данной деятельности.

Организация работы театрального кружка на английском языке является дополнительным средством повышения интереса детей к его изучению, применения полученных знаний в нестандартной обстановке, их развития.

**Актуальность.** Проект ориентирован на всестороннее развитие личности ребенка, его неповторимой индивидуальности, направлен на гуманизацию воспитательно-образовательной работы с детьми, основан на психологических особенностях развития младших школьников.

**Цель работы** – формирование элементарных навыков общения на английском языке у детей младшего школьного возраста, а также мотивация речевой деятельности на английском языке, рост познавательной активности на занятиях внеурочной деятельности через театральное творчество.

**Задачи проекта:** повысить мотивацию учащихся к изучению иностранного языка;

- расширить представления об иноязычной культуре;
- активизировать знания, умения, навыки;
- создать условия для развития интеллектуальных и творческих способностей детей, их самовыражения и самоопределения;
- создать условия, способствующих раскрепощению обучающихся, снятию психологических стрессов, комплексов.

**Целевая аудитория:** учащиеся 2б класса. В кружке занимаются ученики 2 класса, всего 10 человек. У каждого из них есть своя кукла-перчатка. Дети с удовольствием репетируют сказку, с огромным желанием обдумывают декорации.

**Сроки проведения:** январь – май 2018 года

Описание проекта

Проект рассчитан на учащихся начальной школы ( 2 класс) и реализует межпредметные связи с риторикой, литературным чтением, музыкой, технологией, физкультурой. За время реализации проекта его участники должны выбрать сказку для подготовки, выучить слова, придумать и оформить декорации и продемонстрировать итоги своей деятельности.

Этапы проекта

| | **Мероприятие** | **Сроки исполнения** | **Выполнение** |
|---|---|---|---|
| | **<u>Приобретение кукол.</u>** Куклы-перчатки продаются в магазинах детской одежды. В продаже имеются готовые кукольные наборы для разных сказок. Но, | январь | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | сравнивая цены, я сделала заказ в интернет магазине. Через месяц куклы были доставлены. Часть игрушек был приобретен в магазине «Fixprice». Таким образом, можно сделать вывод, что куклы найти несложно. В сети интернет существует огромное множество выкроек изготовления таких игрушек. Если сшить их вместе с детьми, то пользы и увлеченности будет еще больше. Я же попробовала сшить несколько кукол из фетра для пальчикового театра. (Приложение 1) Возможно, это перерастет в еще один новый проект | | |
| | **<u>Подбор сценария для постановки.</u>**<br>Выбор сценария для театра стал очень серьезным вопросом. В сети интернет сложно найти интересные сказки, в основном представлены варианты «Колобок», «Репка», «Красная шапочка». Поэтому я решила составить сценарий сама с учетом имеющихся кукол и уровня владения учащимися языком. Получилась сказка о ёжике, который ищет счастье. (Приложение 2) | февраль | + |
| | **<u>Распределение ролей</u>**<br>При распределении ролей я учитывала языковые возможности учащихся, их моральные качества (ответственность, аккуратность и т.д.), особенности характера каждого. Сначала я предложила роль каждому. Потом они самостоятельно приняли решение по своему желанию. Часть детей согласилась с моим мнением, остальные поменялись между собой. | февраль | |
| | **<u>Репетиции</u>**<br>Репетиции носят систематичный характер, что дает возможность легче запомнить слова сказки. Каждый день после уроков повторяем слова, работаем над произношением, артистичностью.<br>В ходе подготовки к театрализации сказки у учащихся формируются универсальные учебные действия: личностные– дети учатся учитывать и уважать иное мнение (ведь каждый по своему видит, как играть героя), уважать историю и культуру других народов и стран, стремиться к координации различных позиций в сотрудничестве; регулятивные УУД – учимся планировать свои действия в соответствии с поставленной задачей (распределяем роли, создаем декорации и т.д.); коммуникативные - участие в театрализации помогает детям преодолеть «барьер» в изучении английского языка, расширить объем лексико-грамматических знаний, усовершенствовать звуковую культуры | март | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | речи школьников. | | |
| | **<u>Создание декораций</u>** предусматривает подготовку необходимого реквизита и декораций для выступления. Планируется изготовить зеленую поляну с цветами. | март | |
| | **<u>Постановка спектакля</u>**<br>Надеемся представить нашу работу на школьном уровне перед учениками младших классов и перед воспитанниками детского сада. Возможно участие в районном конкурсе. | апрель | |

Перспектива развития проекта

**Ожидаемые результаты:**

1. Повысится интерес к изучаемому языку.
2. Ученики преодолеют барьеры элементарного общения на английском языке
3. У них улучшится память, воображение.

**Возможные риски.** При работе необходимо учитывать возможные риски и альтернативные варианты. Рассмотрим их:

1. Ученики не захотят принимать участие в театре.

Альтернатива – провести мотивационную работу или предложить другому классу.

2. Отсутствие кукол-перчаток в ближайших магазинах.

Альтернатива – сшить их из подручных материалов.

3. Сложности при заучивании слов героев сказки.

Альтернатива – подобрать лексику по возрасту.

**Перспективы развития:**

Этот проект может быть продолжен в следующем учебном году в качестве драматического кружка или возможно реализовать с другими классами.

Заключение

Таким образом, кукольный театр на английском языке имеет ряд преимуществ. Во-первых, повышает мотивацию на начальном этапе изучения иностранного языка. Во-вторых, раскрывает потенциал каждого ребенка, что дает возможность каждому ребенку «найти себя»: занятия в кукольном театре развивают у детей память, мышление, фантазию, артистические способности, знакомят с множеством детских сказок, способствуют развитию общительности, развивают моторику рук и пальцев ребёнка, двигательную активность. В-третьих, в процессе работы над спектаклем дети учатся согласованным действиям, взаимовыручке, умению подчинять свои желания интересам коллектива. В современной реализации концепции ФГОС со временем театральные постановки станут неотъемлемой частью занятий по внеурочной деятельности.

*Список литературы*

1. Захаркина, С.В., Ерхова, У.Л., Атамчук, Е.С. Театр – языковой социум как средство повышения мотивации школьников при обучении английскому языку [Текст]: Иностранные языки в школе. - 2006, август.
2. Рогова, Г.В., Никитенко З.Н. О некоторых путях мотивации школьников при обучении английскому языку [Текст]: Иностранные языки в школе. - 1988, июнь.

# БУЫННАР ҖЫЛЫСЫН САКЛАП

*Йосыпов Наил Зөфәр улы, 5 нче сыйныф*
*Фәнни җитәкче - Йосыпова Райлә Илгиз кызы,*
*Саба муниципаль районы Курсабаш төп гомумбелем бирү мәктәбе*

Шәҗәрә ул - үткәннәрдән
Киләчәккә тәрәзә.
Һәр халыкта, һәр заманда
Шәҗәрәдә дәрәҗә.

Бу сүзләрне язучы Дамир Гарифуллин әйтсә, Башкортстанның халык шагыйре Кадим Аралбай исә “Ал бер үрнәк—бал кортлары төзи кәрәз, син дә ятма: кор ояңны, үр шәҗәрә” дип, безне нәсел-нәсәбебезне белергә, туганнарны, тамырларыбызны барларга чакыра.

Гомумән, татар халкында җиде буын бабаңны белү фарыз гамәлләрнең берсе булып санала. Кеше җирдә үзенең кыска гына гомере эчендә барысына да өлгерергә, барын да танырга, белергә, изгелекләр эшләп калырга, сөенергә, шатланырга, кайгы-хәсрәтне жиңеп чыгарга һәм, иң мөһиме, үзе турында киләчәк буынга якты истәлек калдырырга тиеш.

**Тикшеренүнең актуальлеге**

Үзеңнең кемлегеңне, кайсы нәсел- ырудан булуыңны , туганнарыңны үткәнеңне белми торып киләчәкне төзеп булмый.

**Тикшеренүнең өйрәнелү дәрәҗәсе**

Әби-бабамнар турында ниндидер кыска язмалар бар, ләкин тәртипкә салынмаган, нәсел агачы төзелмәгән.

**Тикшеренүнең максаты һәм бурычы.**

Әлеге тикшеренү эшенең максаты- шәҗәрә төзү.

Хезмәтнең төп бурычы: әти һәм әни ягыннан туганлык җепләрен барлау.

**Фәнни-эзләнү эшчәнлегемне башлау сәбәпләре:** әби-бабамнарның кем булуы, ничек яшәүләре белән кызыксыну. Шәҗәрә төзүгә мин гаилә альбомын материалларына таянып алындым. Апам белән бергә әти-әнидән фотоларда кемнәр болар дигән сорауга җавап эзләдек. Һәрбер фотоның үз тарихы бар икән, материалларны өйрәнүне шулардан башларга булдым , ә алар шактый. Бәхетемә, әбиемнәр һәм бабам исән, алардан да күп сорауларга җавап алдым. Шуларга нигезләнеп гаиләбез шәҗәрәсен төзи башладым. Бу әле аның башы гына.

**Өйрәнү объекты һәм предметы:** әти-әни, әби-бабамнар, дәү әби һәм дәү бабайлар, фоторәсемнәр..

**Тикшеренү методы**: интервью, күзәтү, әңгәмә.

**Хезмәтемнең фәнни-практик әһәмияте:** шәҗәрәне туганнарыма бүләк итә алам.

**Тикшеренүне фаразлау**: әти-әниләр, әби-бабайлардан, туганнардан мәгълүмат алу, фоторәсемнәр белән эшләү.

**Эшнең төзелеше турында мәгълүмат**

Эш түбәндәге өлешләрдән тора: кереш, ике бүлек, йомгак. Керештә кыскача белешмә бирелде, теманың актуальлеге билгеләнде, максат һәм бурычлар куелды.

**II . Төп өлеш. Тамырларым нык, киләчәгем өметле.**

**1. Әти ягыннан нәсел агачы**

Мин , Йосыпов Наил Зөфәр улы, бай табигатьле Саба районы Түбән Утар авылында 2006нчы елның 29нчы октябрендә дөньяга килгәнмен. 2яшьтән Түбән Утар авылы “Салават күпере” балалар бакчасына йөрдем. 2013нче елда Курсабаш төп мәктәбенә укырга кердем. Хәзерге көндә 5нче сыйныфта укыйм.

Бертуган апам Йосыпова Ризәлә 1999нчы елның 19нчы ноябрендә туган.2001нче елдан балалар бакчасына йөргән. 2006нчы елда Түбән Утар башлангыч мәктәбенә укырга

керә, 2010нчы елда Курсабаш урта мәктәбенә 5нче сыйныфка укырга килә. 9нчы сыйныфны гел “5” ле билгеләренә тәмамлый. 2015нче елда мәктәп төп мәктәпкә үзгәртелгәч, 10-11нче сыйныфны Эзмә урта мәктәбендә укыды,алтын медальгә тәмамлады. Мәктәптә уку чорында район, республика, регион олимпиадаларда катнашып, күп мәртәбә җиңүче һәм призер булды. 2016нчы елда Россия мәгариф министрының талантлы яшьләр стипендиясенә лаек булды. Татар теленнән V халыкара олимпиаданың гран-при иясе. Хәзерге көндә КФУ ның Халыкара мөнәсәбәтләр институтында укый.

Әтием-Йосыпов Зөфәр Закир улы, 1973нче елның 25нче февралендә туган. Башлангыч белемне Түбән Утар башлангыч, урта белемне Курсабаш мәктәбендә ала. Мәктәпне көмеш медальгә тәмамлап, КДПУ ның табигать фәннәре факультетына укырга керә.Университетны 1995нче елда тәмамлый, шул көннән башлап Курсабаш мәктәбендә укыта. Әтиемнең 22ел эш стажы бар, ул математика һәм физика фәннәреннән белем бирә. Эшләү дәверендә “Ел укытучысы” конкурсында җиңүче һәм призер булды, ике тапкыр ,”Иң яхшы укытучы” грантына ия, күп санлы мактау грамоталарына ия. Ул укыткан укучылар район, республика, регион олимпиадаларында призлы урыннар алалар, югары уку йортларында укыйлар.

Әтиемнәр биш бала була: Илшат, Илһам абыйлар, әти ,Нурания, Гүзәл апайлар.Әтиемнең әтисе- бабам,Йосыпов Минзакир Зәкәрия улы Татарстан Республикасы (элеккеге Яңа Чүриле районы Арча кантоны) хәзерге Саба районы Түбән Утар авылында 1939нчы елның 10 нчы февралендә туа. Гаиләдә дүрт бала булалар. Әнисе- Минзифа төрле эшләрдә эшли, әтисе – Зәкәрия кладовщик булган. Балачагы авыр сугыш елларына туры килә. Әтисен 30нчы елларда яла ягып төрмәгә утырталар, сугышка шуннан штрафной батальонга, передовойга эләгеп һәлак була. Әтисе киткәч, әнисе җилкәсендә дүрт сабый калалар. Балалар ач булмасыннар дип, әниләре колхоз эшеннән тыш кичләрен тегү тегә, бәйләү бәйли, кешегә абзардан тирес чыгарырга булыша,сепарат аертып көн күрә. Иртә таңнан кичкә кадәр колхоз эшендә булган әниләренә дүрт бала кулдан килгәнчә булышалар: өй эшләрен карау, тавык-чебешне ашату. Колхозга әниләре белән чүп утарга йөриләр, көлтә бәйлиләр, покос әйләндерәләр,фермада ярдәм итәләр. 1945нче елда укырга керә. Башлангыч белемне Түбән Утар мәктәбендә ала, аннары 1949 -1952нче Курсабаш җидееллык мәктәбендә тәмамлый. Ул чорда белем алу җиңелләрдән булмый, укуны дәвам итү өчен районга барырга кирәк. Кеше янына чыгарга кием-салым кытлыгы комачаулый. Көн итү авыр булганлыктан, мәктәп бетергәч, хезмәткә керешә. 1952-1955нче елларда ике елы хуҗалык көтүе, бер ел колхозда сарык көтүе көткән.1955 нче елдан-1958 нче елга кадәр “Победа” колхозында атлы эштә эшли башлый. 1958-60 нчы елларда тракторда прицепщик булып эшли.1960-64 нче елларда завферма булып хезмәт куя.1964елдан-1986нче елга кадәр бригадир булып эшли. Яхшы эшләгәне өчен”Коммунистик хезмәт ударнигы исеме” бирелә 1967нче елда тракторист- машинист таныклыгы ала. 1978-1981нче елларда Минзәлә совхоз-техникумында читтән торып агрономлыкка укый.1986-1990нчы елларда агроном булып эшли , партоешма секретаре да, шул чорда арендага җир алып, 1993-2002нче елларда зампред булып эшләп, лаеклы ялга чыга. Яхшы эшләгәне өчен “Хезмәт ударнигы” исеме бирелә.

1981нче елда Зәки Хәбибуллин исемендәге премия.1991 нче елда Зәки Хәбибуллин исемендәге премия диплом социалистик ярышта 1урынны алган өчен, 1981нче елда ашлык һәм бәрәңге үстерүдә зур уңышларга ирешкәне өчен Почетная грамота белән бүләкләнә.

1977нче елда Почетная грамота “Победа” колхозы социалистик ярышта яхшы күрсәткечләргә ия булган өчен,1989нчы “Победа” колхозында күпьеллык хезмәте өчен “Почетная грамота” белән бүләкләнә.2000нче елдан лаеклы ялда.

Бабамнар гаиләдә 4 бала- Кави, Заһит абый, бабам, Рауза апа булалар. Закир бабамның бабасы Йосыф, дәү бабасы Төхбәтулла була. Әтием ягыннан үземне санап 6 буынга кадәр нәселемне белә алдым.

Әтиемнең әнисе, Йосыпова Кадрия Фазылҗан кызы, Татарстан Республикасы (элеккеге Яңа Чүриле районы Арча кантоны) хәзерге Саба районы Түбән Утар авылында

1939нчы елның 19нчы июнендә туа. Гаиләдә ике бала булалар. Әнисе- Маһруйбикә төрле эшләрдә эшли, әтисе – Фазылҗан кибетче булган. Әнисе сугыш чорында окоп казырга барган, урман чыгарган. Балачагы авыр сугыш елларына туры килә.Әтисе сугышка киткәч, әнисе җилкәсендә ике сабый калалар. Әтисе сугышта склад сакчысы булган. Балалар ач булмасыннар дип, әниләре колхоз эшеннән тыш кичләрен тегү тегә, бәйләү бәйли. Иртә таңнан кичкә кадәр колхоз эшендә булган әниләренә ике бала кулдан килгәнчә булышалар. 1946нчы елда укырга керә. Башлангыч белемне Түбән Утар мәктәбендә ала, аннары Курсабаш җидееллык мәктәбендә укый. Көн итү авыр булганлыктан, мәктәп бетергәч, Шәмәрдәнгә бала карарга менә. 1955 нче елда “Победа” колхозы фермасына дуңгыз карарга керә. Яхшы эшләгәне өчен”Коммунистик хезмәт ударнигы исеме”. “Ударник девятой пятилетки” исеме бирелә. 1964нче елдан колхозда төрле эшләрдә эшли башлый.

1984-1994 нче елларда Түбән Утар авылында почтальон булып эшли. Элемтә органнарында намуслы хезмәт куйганы өчен Почетная грамота белән бүләкләнә.1994 нче елдан лаеклы ялда.

Кадрия әбиемнең бабасы Сабирҗан, дәү бабасы Гыйльман исемле була. Әбинең әтисе Фазылҗан Бөек Ватан сугышында катнашып, хәбәрсез югала.Әтинең әнисе ягыннан да 6нчы буын баласы мин.

Әбиемнәр гаиләдә ике бала: Габтерафыйк абый һәм әби.

**2.Әни ягыннан нәсел җебе.**

Әнием- Йосыпова Райлә Илгиз кызы Саба районы Тимершык авылында 1973нче елның 24нче февралендә туган. Тимершык урта мәктәбен көмеш медальгә тәмамлап, КДПУның тарих- филология факультетына укырга керә. Тарих, татар теле һәм әдәбияты укытучысы белгечлеге буенча 22ел эшли.Эш урыннары- Казан шәһәре Яңа Савин районы 155нче татар-инглиз гимназиясе һәм Курсабаш мәктәбе. Әниемнең дә эш нәтиҗәләре куанычлы. Укучылары республикакүләм конкурсларда, район олимпиадаларында уңышлы чыгыш ясыйлар.

Әниемнәр дә биш бала: әни, Гөлзада, Диләрә, Гүзәл апай, Илфар абый.

Әни ягыннан бабам – Габделхаев Илгиз Габделхәй улы, 1941нче елның 13нче гыйнваренда Саба районы Югары Симет авылында туа. Бертуганнары сугыштан соң туалар: Сөмбелә, Гөлсәрия, Зөлхәбирә, Венера ( бала чакта үлә), Габделнур. Югары Симет дүртъеллык мәктәбен тәмамлый. Тормышлары авыр булганлыктан, Түбән Симет җидеелык мәктәбен тәмамлагач, Кукмарадагы Янил училищесына тракторист- машинистка укырга керә. Гомеренең 32елында тракторда эшли, сәламәтлеге какшагач, фермада терлекче була.2001нче елдан лаеклы ялда. 2010нчы елның 27нче гыйнварында вафат булды.

Илгиз бабамның әтисе Габделхаков Габделхәй Хак улы Бөек Ватан сугышында катнашып, исән –имин әйләнеп кайта. Сугыштан соң колхоз рәисе, бригадир булып эшли. 1981 нче елда вафат. Дәү бабайлар Фәйрүзә апай, Разыя апай, бабай булалар. Әниемнең әтисе ягыннан 5нче буын баласы булам, ә әнисе ягыннан 6нчы буын булам

Илгиз бабамның әнисе- Габделхаева Фатыйма Нигъмәтҗан кызы Арча районы Курса Почмак авылында туып-үскән, дәү бабама кияүгә чыккан. Дәү әбиемнең бабасы Хәкимҗан исемле була.

Әниемнең әнисе-Хаева Гөлфарах Әхсән кызы 1939 нчы елның 6 нчы февралендә Саба районы Тимершык авылында туа. Әхсән белән Шәрифелҗамалның сигезенче баласы була ул. Шул сигез баланың бары өчесе генә Минҗиһан, Гөлзәйнәп, минем әбием генә исән – имин үсеп буйга җитәләр, дүрт малай һәм бер кызлары төрле сәбәпләр белән үлеп китә.

Гөлфарах Әхсән кызына тормышның барлык авырлыкларын кичерергә туры килә. Балачагы авыр сугыш еллары һәм сугыштан соңгы чорда үтә . Тимершык җидееллык мәктәбенә 1947нче елда укырга керә, яхшы билгеләренә укый. 1954 нче елда мәктәпне тәмамлый, гаилә хәле укуын дәвам итәргә мөмкинлек бирми. Эш сорап сарык фермасына килә. Буең кечкенә дип анда эшкә алмыйлар, ел ярым артельдә бияләй тегүче булып эшли. Аннары яшьтәшләре кебек сарык фермасында эшли. Ике ел эшләгәч, сарыкларны Көеккә

алып китәләр, ул бозау һәм таналар карый, берничә елдан сыер савучы булып хезмәт куя. 1966, 1967, 1968 нче елларда яхшы эшләгәне өчен район слётында бүләклиләр.

1969 нчы елда тормышка чыга. Ире Илгиз белән дүрт кыз, бер малай тәрбияләп үстерделәр. Балалары да үзе кебек тырышлар, хезмәтләрендә мактаулылар.1984 нче елда бала тәрбияләүдә үрнәк әни булганы өчен“Ана” медале белән бүләкләнде. Бу чорда колхозда төрле эшләрдә эшли: амбарда ашлык чистарту, симәнә агулау, капчык ямау, басуда чөгендер, кәбестә, кишер җирләрен эшкәртү, язын бәрәңге калибрлау, көзен бәрәңге чүпләүдә тырыш хезмәтен куя.

1988-1990нчы елларда хат ташучы вазифасын башкара. 1989нчы елда лаеклы ялга чыга. Хәзерге көндә тормышына шөкер итеп, Тимершык авылында яши.

Дәү бабай- Галимуллин Әхсән Галимулла улы 1899 нчы елның 4нче апрелендә туган. Совет-фин һәм Бөек Ватан сугышларында катнашкан. Ул алтын куллы балта остасы, итек басучы була, шул һөнәрләре ачлык-ялангачлык чорында бик ярдәм итә. Авылдагы бик күпләрнең тәрәзә йөзлекләре, ат чанасы, арбасы, урындык - өстәл, эскәмия, арба күчәре, тәгәрмәчләр һ.б-лар аның кулыннан үтә. Колхозның агач мастерскоенда эшли.1958нче елның 18 нче июлендә вафат була.Әхсән бабамның әтисе Галимулла була. Аның турында мәгълүматлар әлегә әз.

Дәү әби - Галимуллина Шәрифелҗамал 1899 нчы елның январь аенда туган. 1921нче елгы ачлык турында менә болай сөйли ул: “Матчада чиләк, чиләк төбендә әз генә он. Онга кагылырга ярамый, кашык очына гына элеп кычытканлы ашка болгатабыз, шуннан бер чама хәл кергәндәй була. Шулай әздән генә ачтан үлми исән калдык”. Ул колхозда төрле эшләрдә хезмәт куя. 1985 нче елның 30 нчы маенда үлә.

**III. Йомгаклау**

Бу эзләнүләрдән мин нәселем турында бик күп нәрсәләр белдем. Нәселемнең нинди зур, горурланырлык бай тарихы бар икән бит. Нинди генә авыр чорда яшәсәләр дә, алар төшенкелеккә бирелмәгәннәр, һәрчак алга атлаганнар, батыр, горур булып калганнар. Әби-бабаларыбыз мирасын,тәрбиясен буыннан-буынга тапшыру, нәселебез шәҗәрәсенә тап төшермичә яшәү- безнең бурычыбыз. Үткәннәрне барлап, киләчәккә күз төбәп яшәргә кирәк. Киләчәктә дә нәселебез шәҗәрәсен тирәннән өйрәнүе үземнең бурычым дип саныйм, чөнки безгә якын кешеләребез, үз нәселебез аша халкыбызның үткән юлын, чал тарихын сөйли.

Эш барышында тамырларымның шактый нык булуын аңладым. Әле мин шәҗәрәне туры линия буенча гына төзедем, һәр буынның балаларын күрсәтеп тармакландырасы бар. Нәсел агачыннан күренгәнчә, мин 6нчы буын баласы. Эшемне туганнан туганнарымны барлап дәвам итәрмен. Аларның яшәү географиясе бик киң. Бурятия, Иркутски, Екатеринбург, Үзбәкстан, Казан, Буа, Шәмәрдән, Саба, Югары Симет, Тимершык,Арча, Курса Почмак, Эзмә, Түбән Утар, Югары Утар исемнәре белән бәйле. Әбием белән бабам бик күп әйберләр сөйләделәр, яшьлекләрен сагынып искә төшерделәр. Мин үз фамилиям чыгышын белдем. Ул чорда этиләренең исеме күп вакыт фамилия дә, отчество да булып торган икән. Мин үз нәселем белән чиксез горурланам.

Шәҗәрә агачын, буыннар тезмәсен, гаилә тарихын төгәл эшләү өчен төрле мәгълүмат туплау шактый вакыт сорый, тапкан материалларны җентекләп тикшерүне таләп итә. Нәселнең өзелмәс җепләр белән уралган язмышлары аша без бүген төрле җирләрдә сибелеп яшәгән нәсел-ыруыбыз барлыйбыз.Нәсел, гаилә тарихы ул илнең дә тарихы. Ул һәр кешенең эшенә һәм тормыш юлына. Күпсанлы кардәш-ыруның бәйләнешләренә ачыклык кертә.

*Чыганаклар*

1. Хаева Гөлфарах әбием истәлекләре
2. Йосыпов Минзакир бабам истәлекләре
3. Йосыпова Кадрия әбием истәлекләре
4. Гаилә альбомы

## БУЫННАР ЧЫЛБЫРЫ ӨЗЕЛМӘС ...

*Йосыпова Рәзилә Ренатовна, 5 класс*
*Биктова Раилә Рубертовна,*
*МБГБУ "Яңа Кенәр урта гомуми белем мәктәбе”,*
*Арча районы*

**1.Укытучы һөнәре**.

Һөнәрләрнең бар җайлысы,һөнәрләрнең бар яхшысы,һөнәрләрнең бар авыры...Ә укытучы хезмәте - изге һөнәрләрнең берсе.Шулай булмыйча мөмкин түгел,укытучы шәхес тәрбияләүче,үзенең беренче адымын ясаучы,укучыга юл күрсәтүче.Укытучы - ул юк кына “ташбаш малай”ны да игътибар белән кадерләп багучы, өметсез “сәләтсездән”дә,имансыз “юньсездән”дә җан җылысын җәлләмичә,һәрберсен шәхес итеп танучы.

Бу эшемнең **максаты** да укытучы һөнәренең авырлыгы турында

күбрәк мәгълумат туплау; алар турында язучы һәм композиторларның әсәрләрен белү ; буыннан буынга күчеп килүче бу һөнәрне тирәнтен яктырту, укытучыларга карата ихтирам, мәхәббәт тәрбияләү.

**Бурычлар:** төрле һөнәрләр белән танышу, әбием һәм әнием һөнәрләре белән якыннан таныштыру,бу һөнәргә кызыксыну уяту.

Әйе,хөрмәтле остаз белән бергә,аңа таянып ясалган беренче адымнар күпләргә тормышта үз юлларын салырга ярдәм итә.Үзе тәрбияләп, “зур тормышка” озаткан балаларның уңышларын,бөртекләп,барлап торган педагогның акыллы да,матур да фикерләре һәр укучының күңелендә урын ала.Ә укытучы күңелендә-горурлык хисе.Бакчачы гөлбакчада үскән гүзәл гөлләре белән мактангандай,чын укытучылар да чәчәкләре җимешләнгән укучылары белән соклана.Шулай булмый ни,бер бала тәрбияләп үстерү генә дә ни тора,ә дистәләгән-йөзләгән нарасыйны җәмгыяткә кеше итеп әзерләп бирү күпме көч,күпме сабырлык,никадәр нур сорый?! Шул фидакарьлек,күңел юмартлыгы элек-электән аерып торган бит инде аларны! Аларның изге күңеллелеге алиһәдәй бөек,әнидәй якын кеше дәрәҗәсенә күтәрә. Ә без,укучылар,үз чиратыбызда,үзебез ирешкәннәрне алар алдында горурланып күрсәтергә,алар белән уртаклашырга ашыгабыз.

1991 елдан бирле 5 октябрьдә укытучылар көне билгеләнеп үтелә.Ә Россия хөкүмәте тарафыннан 2010 нчы ел Укытучылар елы дип игълан ителде.

Укытучы – дөньяны танып – белергә омтылучы, балаларның керсез пакь күңелләренә гыйлем орлыклары чәчүче һәм аларның тигез матур шытымнар бирүен сабыр гына көтүче Остаз, газизләрдән – газиз әниләр белән берүк дәрәҗәгә куярлык изге зат. Шулай ук балаларның нечкә саф күңеленә саклык белән генә кагылучы, аларга хаклык энҗеләрен тезүче оста киңәшче психолог та, уку барышында юл күрсәтүче маяк та, алай гына түгел, укытучы ул – ил- көндә барган һәр яңарыш, һәр борылыш, һәр үзгәрешне үз аңы аша үткәреп, алгарыш мәйданында җинү яулашкан каһарман шәхес тә!

**2 .Укытучылар турында язучыларыбыз.**

Укытучылар турында безнең күп кенә язучыларыбыз шигырьләр иҗат иткәннәр: Резеда Вәлиева, Атлас Галимов, Мәкмүнә апа Нәҗипова,Фәнис Яруллин сүзләренә җырлар. Укытучы шәхесен, аның яшәеш һәм хезмәте үзенчәлекләрен сүз сәнгате аша гәүдәләндерүдә әдипләргә ярдәм иткән чыганаклар:

-халык авыз иҗаты әсәрләре: белем-тәрбия турында халык мәкальләре, җырлар, балалар фольклоры һ. б.;

-халыкта гаилә тәрбиясе традицияләре (мәсәлән, Г. Тукайның “Ана мәктүпләре”, Һ. Такташка, Х. Туфанга әниләре тәрбиясе йогынтысы);

-укымышлы ата-аналар һәм гаиләдәге белем-тәрбия ;

-укытучы әдипләр (Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимов, Г. Кутуй, Ш. Усманов, М. Мәһдиев, Ш. Маннур, Х. Туфан, С. Сөләйманова, К. Булатова).

**Хәтерлим мин, әле бүгенгедәй,**
**Сентябрьнең бере җиткәнен.**
**Хәтерлим мин, әле бүгенгедәй,**
**Укытучы апам көткәнен.**
**(Э. Мөэминова. "Укытучыма" шигыре)**

Безнең барыбызны да хәреф танырга, укырга, язарга өйрәтүчеләр бар. Алар – укытучылар. Ә менә беренче укытучы һәркемнең күңелендә, якты истәлек булып, гомер буе саклана. Еллар үтсә дә, без аны хөрмәт белән искә алабыз. Шушы юлларны укыгач, әлеге хатирәләр күңелләребездә кабаттан яңара.

Резеда Вәлиева шигърияттендә дә укытучы темасы бар:

**Ул өйрәтте каләм тотарга һәм**
**Тәүге сызыкларны сызарга.**
**Ул өйрәтте хәрефләрне теркәп,**
**Иҗекләрдән сүзләр язарга.**
**Күзәтте ул һаман гомерем юлын,**
**Ялгышларым булса, төзәтте.**
**Хезмәт яратырга, туган җиргә**
**Тугрылыкка мине өйрәтте.**
**Кыенлыклар килсә, әледә ул:**
**"Бирешмә!" – ди гүя, эндәшә.**
**Күңелемдә шулай гомерем буе**
**Укытучым килә янәшә.**
**("Укытучым")**

Мөгаллимнәр турындагы күп кенә җырларга композиторлар көй язганнар. Н. Хашимованың "Укытучыма" шигыре бар. Аңа Р. Курамшин музыка чыгарган.

Шагыйрә Саҗидә Сөләйманова белән композитор Мәсгут Имашев мәктәпне тәмамлаучыларга "Саубуллашу вальсы" язалар.

Шәүкәт Галиевнең "Кыңгыраулы мәктәп еллары" шигыренә композитор Рим Хәсәнов көй яза.

**Әйтерсең лә пар атларда үтте**
**Кыңгыраулы мәктәп еллары.**

Ә менә Фәнис Яруллин үзенең "Иң гүзәл кеше икәнсез" шигырендә укытучыга хас булган "күркәм", "гүзәл", "сабыр" кебек сыйфатларның һәрберсенә бер строфа багышлый. Мисалөчен:

**Килгән чакта башка авырлык,**
**Җитми калсакөч я сабырлык,**
**Сиздермичә ярдәм иткәнсез –**
**Сез иң күркәм кеше икәнсез.**

Шигырьгә Әхмәт Хәйретдинов музыка яза.

М. Кәрим сүзләренә А. Кобагышев көй язган "Укытучыма" җыры да бар.

**3.Әбием һөнәре**

Минем әбием -Йосыпова Рәмзия Мөдәрис кызы.Ул 1960 нчы елның 24 нче мартында иситкеч гүзәл табигатьле Мәмсә авылында туган. Кечкенәдән укытучы булырга хыялланган .Шушы хыялы аны Арча педагогия училищесына китергән.1975-1979 нчы елларда анда белем алып, укытучы һөнәренә өйрәнгән.1979 нчы елның 15 нче августыннан башлап ул Яңа Кенәр интернат-мәктәбенә килеп эшли башлаган һәм бер генә урында 33 ел тоташ эшләп лаеклы ялга чыккан.Булган белеме белән генә чикләнеп калмаган әбием,Казан дәүләт педагогия институтында югары белем дә алган. Эшләү дәверендә шатлыклы минутлары да,борчулы вакытлары да күп булган әбиемнең.Чөнки бу мәктәптә ятим балалар укыганнар.Әбием үзенең бөтен көчен биреп укучыларын дөрес укырга һәм язарга, матур итеп үз фикерен җиткерергә, яхшылыкны күңеленә сеңдерергә , тормышны аңларга, аны яратырга өйрәтә,чын күңелдән аларның уңышына шатлана һәм горурлана.

Аларга әниләр кебек мәрхәмәтле,шәфкатьле ,кирәк булганда назлы,ягымлы да булган.Шулай булмый ни, укытучы һөнәренә ия булган кеше- дөньяны танып – белергә омтылучы, балаларның керсез пакь күңелләренә гыйлем орлыклары чәчүче һәм аларның тигез матур шытымнар бирүен сабыр гына көтүче Остаз, газизләрдән – газиз әниләр белән берүк дәрәҗәгә куярлык изге зат. Шулай ук балаларның нечкә саф күңеленә саклык белән генә кагылучы, аларга хаклык энҗеләрен тезүче оста киңәшче психолог та, уку барышында юл күрсәтүче маяк та.

Әбием бүгенге көндә дә үзенең педагогик осталыкларын күрсәтеп мине һәм энемне тәрбияләүгә күп көчен куя. Миңа дәресләремне әзерләшергә булыша,төпле киңәшләрен бирә.Энем Ризат белән минем өчен ул үрнәк кеше.Без аны бик яратабыз. Әти-әнисеннән күчкән тырышлык, максатка омтылучанлык сыйфатлары – әбиемнең гомерлек юлдашлары.Шушы ук сыйфатларны ул бездә дә тәрбияли.Ул сүз белән түгел, ә тырыш хезмәтенең нәтиҗәләре, уңышлары белән дә үрнәк булып тора.Урын кешене бизәми,кеше урынны бизи, ди халык мәкале.Нинди генә бәяләр алса да,ул искиткеч гади, кече күңелле укытучы минем өчен.Аның белән һәрвакыт борчыган соравыңа җавап табып,уй-хисләрең,кичерешләрең белән уртаклашып,күңелеңә кирәкле җавапны таба аласың.Ягымлы карашы ,нурлы йөзе , тәмле теле, телеңне йотарлык итеп әзерләнгән ризыклары белән безне һәрвакыт үзенә тартып тора. Әбием,сиңа сәламәтлек,озын гомер, тыныч тормыш телим.

**4.Әнием-укытучы**

Минем әнием -Йосыпова Рәйсә Фаил кызы.Ул да шулай ук әбием кебек укытучы һөнәрен сайлаган. Әнием дә әбием эшләгән Яңа Кенәр мәктәп-интернатында укыта.Хәзер инде монда сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән балалар укый.

Әнием һәр укучыга шәхси якын килә, аларга зур шәхес итеп карый. Баланың үз-үзенә ышанычын үстерә, өмет хисе тәрбияли, төшенкелекләргә урын калдырмаска тырыша.

“Чын укытучы үз эшенең нәтиҗәсе яхшы булсын өчен бөтен күңелен биреп эшли, балаларның язмышы өчен борчыла.

Һәр баланың кечкенә генә булса да сәләтен күреп, аны үстереп, балада үз-үзенә карата ышаныч тудырып, кирәк икән бәхәсләшеп, көтелгән нәтиҗәгә дусларча мөнәсәбәт аша ирешергә мөмкин. Һәр балага шәхес буларак формалашырга, тормышта авырлыклар алдында каушап калмаска, аны үз гамәлләренә һәм хезмәтенә дөрес бәя бирә алырдай итеп тәрбияләргә бурычлы без”-ди әнием.

Әнием белем, тәрбия бирүдән тыш төрле эшләргә дә катнаша. Бәйрәмнәрдә концерт, театр куючы да ул ,җәй көне бакчада чәчәк үстерүче, кыш көне кардан сыннар ясаучы да ул. Үз белемен күтәрү өстендә туктаусыз эшли. Белем күтәрү курсларында укый, семинарларда, һөнәри конкурсларда катнаша.

**Әниемнең җылы кочагы**

Сөекле әниемнең
Борчыгандыр җанын
Күңелемнең көйсез һәр чагы,
Еласам, юаткан,
Иркәләп уйнаткан
Әниемнең җылы кочагы.

**5. Хыяллар,хыяллар.**Һөнәрлеуттаянмый, суда батмый”. Бумәкальэчендәникадәрле сер яшеренгән. Ә нәрсәсоңулһөнәр? Һөнәрулбарыбызга да танышсүз. Бу кем өчендер-яратканэше, нәрсәбулсадаҗитештерү, һөнәр –улбелгечлек, профессия. Һөнәрләр...Ниндиегенәюк бит аныңбудөньяда?! Укытучы, табиб, шофер, пешекче һәмбашкалар ,аларминемчәмеңләгән. Барысы да мөһимһәм кирәкле. Шофер буласыңкиләикән-шофер бул, тракторчыбуласыңкиләикән –тракторчы бул. Һөнәрнесайлыйгына белергәкирәк. Һөнәрне яратып, күңелеңә ятышлысын сайласаң гына, һөнәреңнең остасы була аласың. Мәсәлән, укытучы булуөчен–сабырлык, балаларны ярату,

табиб булу өчен–игътибарлык, пешекче булу өчен–күңелең белән пешерергә кирәк. Һөнәр сайлау–минем өчен җаваплы эш. “Һөнәр кулдагы беләзек”, диелгән мәкальдә.

Әнием миннән бервакыт кем булырга теләвем турында сорады. Мин югалып калдым, һөнәр сайлау бит ул- бик авыр һәм җаваплы адым.

Шул көннән бирле,мин һәркөн бу сорау турында уйлыйм. Кечкенә чагымны, беренче тапкыр мәктәпкә баруларымны искә төшердем. Күз алдыма балалар бакчасындагы тәрбиячеләрем,беренче укытучым килеп басты. Һәм мин бер карарга килдем: укытучы булам. Минемчә,укытучы- иң мактаулы һәм иң намуслы кеше. Укытучыдан башка беркем дә һөнәргә өйрәнә алмый. Укытучы-барлык һөнәрләргә юл ачучы кеше. Шуның өстенә, алар әле һөнәр генә түгел, ә тәрбия дә бирәләр.

Әгәр дә мин укытучы булсам, һәр укучымны ихтирам итәр идем,чөнки һәр кеше,шул исәптән, бала да-шәхес бит.

Укытучы булсам, мин дәресләрне кызыклы, балалар сулыш алырга да онытып, кызыксынып, игътибар белән тыңларлык итеп үткәрер идем. Мин аларга слайдлар, проекция экраннарында компьютер программалары күрсәтер идем. Бөтен биремнәрне принтерда яхшы кәгазьдә бастырып бирер идем. Һәрбер карточка темага туры килгән рәсемнәр яки фотографияләр белән бизәлгән булыр иде. Мин һәр укучының партасында компьютер торуын булдырыр идем һәм күпчелек биремнәрне өйрәтүче программалар рәвешендә бирер идем. Ә билгеләр икәү генә булыр иде : "үти алган" һәм "әлегә йомшаграк".

Билгеле инде , беренче укытучым Биктова Раилә Руберт кызын да үземә укытучы буларак үрнәк итеп куям. Беренче хәрефне танырга, уку-язуга кызыксыну уятты ул миндә. Игелекле, намуслы, әдәпле булырга, туган җирне яратырга, халкыбыз белән горурланырга өйрәтте.

Укытучының бурычы- сәламәт, әдәпле, тәрбияле, сәләтле балалар тәрбияләү. Минем дә балаларны яхшылыкка, әдәплелелеккә, тату булырга өйрәтәсем килә. Әлбәттә, мин моңа ышанам. Киләчәктә мәктәпне яхшы билгеләргә генә тәмамлап, үз хыялымны тормышка ашырсам,әбием һәм әнием үрнәгендә гаилә династиясе чылбырын дәвам итсәм,мин бик бәхетле булыр идем.

**III.Йомгаклау**

Җир йөзендә һөнәрләрнең һәркайсы үзенчә җаваплы, ихтыяр көчен таләп итә. Һәр әти-әни үзенең баласын төпле итеп үстерергә тели. Билгеле бер өлкәдә ышанычлы кеше итеп күз алдына китерә. Кеше үзенә ошаган һөнәрне юлдаш итеп сайлый белергә тиеш. Һөнәр кешегә матди яктан гына түгел, ә җан тынычлыгы бирә торган да булырга тиеш дип уйлыйм мин.

Сайлаган һөнәрең хәтердә җуелмас якты нур калдырырлык матур да, рәхмәтле дә булсын өчен нишләргә? Укытучыларга хас иң мөһим сыйфатлар нинди? Балаларны ихластан ярату, зирәклек,намуслылык,таләпчәнлелек - болар бар да безнең укытучыларыбызга хас сыйфатлар. Рәхмәт Сезгә,хөрмәтле укытучыларыбыз! .

Мин үземнең куйган максатларыма ирештем дип саныйм, шушы һөнәргә ирешү өчен бар көчемне туплап алга барачакмын, тырышып укыячакмын.

*Кулланылган әдәбият*

1.Гыймадиева Н.С., Галләмова Р.В. Үзебез язабыз .Башлангыч сыйныфлар өчен сочинениеләр.- Казан : "Гыйлем нәшрияты".- 2008

2.Рифә Рахман . Һәр сыйныфта-сочинение. Мәктәп укучысына ярдәмлек . Казан : "Раннур" нәшрияты , 2008

3.Табышмаклар ,мәкальләр һәм әйтемнәр, сынамышлар.Казан : "Гыйлем нәшрияты" , 2014

belem.ru

nsportal.ru

# КӘРИМ ТИНЧУРИННЫҢ “СҮНГӘН ЙОЛДЫЗЛАР” ДРАМАСЫ, ТӨП ОБРАЗЛАРГА ХАРАКТЕРИСТИКА

*Карпова Елизавета Семёновна,*
*МБГБУ “с.Село-Чура урта гомуми белем мәктәбе”,*
*Кукмара муниципаль районы*

**Дәреснең темасы:** Кәрим Тинчуринның «Сүнгән йолдызлар» драмасына анализ. Төп образларга характеристика бирү. (Әдәбият, 8нче сыйныф)

**Максат:**

- укучыларны күренекле драматург Кәрим Тинчуринның иҗаты белән таныштыруны дәвам итү, образларга характеристика бирү, драмага анализ ясау;
- тормыш тәҗрибәсе бирү, укучыларның фикерләү сәләтен һәм бәйләнешле сөйләмен үстерү;
- тормышта үз урыныңны табу, үз бәхетең өчен көрәшү һәм рухи ныклык сыйфатлары тәрбияләү.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр**:

***Шәхескә кагылышлы :*** укучыларны аралашырга, бер-берсенең фикерләрен хөрмәт итәргә өйрәтү, тормышта үз урыныңны табу, үз бәхетең өчен көрәшү һәм рухи ныклык сыйфатлары тәрбияләү .

***Предмет буенча:*** укучыларны драма жанры белән таныштыру; «Сүнгән йолдызлар» әсәренең эчтәлеген аңлау; тема, проблема, сюжет-композициясе өстендә эшләү; образларны система рәвешендә күзаллый алу.

***Метапредмет:*** әдәбият белән тарих бәйләнешен ассызыклау.

***Танып-белү (УУГ):*** үзләренең белем системасында ориентлаша белергә өйрәтү; яңа белемнәр табу; үткәндә өйрәнгәнне укытучы ярдәмендә яңасыннан аера белү; дәрестә алган мәгълүматлардан файдаланып, сорауларга җавап бирү.

***Коммуникатив (УУГ):*** сорауларга җавап бирү, үз фикереңне аңлы һәм дөрес җиткерә алу, коллектив әңгәмәдә катнашу.

***Регулятив (УУГ):*** уку максатын куя белү,үз-үзеңне бәяләү, хаталарыңны төзәтү.

**Дәрес тибы:** әдәби әсәрне анализлау.

**Предметара бәйләнеш**: әдәбият, тарих

**Ысуллар:** тикшеренү, эзләнү.

**Җиһазлау:** проектор, китапларыннан күргәзмә, анализ үрнәкләре.

**Материал:** Ф.Ә.Ганиева, Ч.Р.Рамазанова Әдәбият 8 нче сыйныф – 2нче кисәк; К.Тинчурин. Сайланма әсәрләр; Заһидуллина Д.Ф., Закирҗанов Ә.М., Гыйләҗев Т.Ш. Татар әдәбияты .Теория. Тарих. – Казан: Мәгариф, 2004; «Сүнгән йолдызлар» спектакленең видеоязмасы.

**Дәрес барышы**

**I. Оештыру, мотивлаштыру.**

1.Исәнләшү.

2. Уңай психологик халәт тудыру.

**II. Белемнәрне актуальләштерү.**

1. Тест ярдәмендә укучыларның әсәр эчтәлеген ни дәрәҗәдә белүләре тикшерелә.

1. КәримТинчурин кайчан туган?

а) 1906 елның 15 феврале

б) 1887 елның 15 сентябре

в) 1901 елның 1 гыйнвары

2. “Сүнгән йолдызлар” әсәре

а) драма

б) хикәя

в) повесть

3. “Сүнгән йолдызлар” драмасының авторы
а) Г.Камал
б) К.Тинчурин
в) М.Фәйзи
4. “Сүнгән йолдызлар” драмасының төп герое
а) Сәрвәр
б) Фатыйма
в) Гөлнур
5. “Сүнгән йолдызлар” драмасында Сәрвәр кем белән кала?
а) Исмагыйль
б) Надир
в) вафат була
6. “Сүнгән йолдызлар” драмасында Исмагыйль нинди төш күрә?
а) бай булуын
б) йолдызлар сүнүен
в) сугыш башлануын
7. “Сүнгән йолдызлар” драмасында, сугыш башлануын ишеткәч, Надир нәрсә эшли?
а) кайгыра
б) борчыла
в) шатлана
8. “Сүнгән йолдызлар” драмасында ни өчен Сәрвәр Исмәгыйльнең колагына дару сала?
а) коткарып калу өчен
б) сугышка җибәрмәү өчен
в) дәвалау өчен
9. “Сүнгән йолдызлар” драмасында Сәрвәрнең акылдан язуында кем гаепле?
а) Надир
б) Исмагыйль
в) сугыш
2. Экранда җаваплар чыга, укучылар тикшерә һәм үзләренә бәя бирә.
9 дөрес җавап – “5”
7. дөрес җавап – “4”
6. дөрес җавап – “3”

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

**Укытучы.** Укучылар, сез өйдә Кәрим Тинчуринның «Сүнгән йолдызлар» драмасын укып килдегез, әбүгенге дәреснең темасы нинди булыр икән?

*Көтелгән җавап.* Бүгенге дәреснең темасы: Кәрим Тинчуринның «Сүнгән йолдызлар» драмасына анализ.

**Укытучы.** Без дәрестә ни белән шөгыльләнәчәкбез?

*Көтелгән җавап.* Әсәрнең сюжетын кыскартып сөйләячәкбез, конфликтны табарбыз, образларга бәя бирербез.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

1. Сюжетны кыскартып сөйләү.

**Укытучы.** Укучылар, үзегез билгеләп үткәнчә, драманың сюжетын кыскартып сөйләгез әле.

*Көтелгән җавап.* Хәзрәттә хезмәт итүче ятим егет Исмәгыйль Сәрвәрне ярата. Әбисе белән генә яшәүче кыз да аның мәхәббәтен кабул итә. Мәхдүм Надир, хат язып, Сәрвәрне яратуын белдерә. Ләкин сугыш башлана. Егетләрнең бер өлеше төрле юллар белән солдаттан кала, бер төркемен сугышка алып китәләр. Сәрвәрнең дә сөйгәненнән аерыласы килми .Ул үз куллары белән Исмәгыйль колагына «дару» сала. Егет үлә. Сәрвәр акылдан яза, соңрак сөйгәне кабере өстендә җан бирә. «Соңгы өмете», «актык йолдызы» булган Сәрвәр үлеменнән соң Надир үз-үзенә кул сала.

2. Драма әсәрләренә анализ ясау тәртибе искә төшерү ( экранда чыга, шулай ук һәр партада анализ үрнәге бар)

**Драма әсәренә анализ тәртибе**

1. Жанры (драма, трагедия, мелодрама, комедия, водевиль;, музыкаль комедия һ.б.), аны билгеләүче сыйфатлар.
2. Темасы (әсәрдә яктыртылган тормыш-күренешләре).
3. Конфликты (төп конфликт, ярдәмче конфликтлар; аның персонажлар арасындагы мөнәсәбәтләрдә, аларның эш-хәрәкәтләрендә, уй-фикерләрендә һәм омтылышларында чагылышы).
4. Сюжеты (аның үсеше, төп сюжет сызыклары). Сюжет һәм композиция.
5. Образлар системасы (төп һәм ярдәмче; актив һәм пассив; уңай һәм тискәре; аларның сыйфатларын билгеләүче факторлар).
6. Драма әсәренә хас элементлар (персонажлар исемлеге, ремаркалар, декорация, диалог, индивидуаль сөйләм һ.б.) һәм аларның автор идеясен, образларны ачудагы роле.
7. Идеясе.
*8. Әсәрнең әһәмияте (идея-эстетеик кыйммәте, тәрбияви роле, әдәбиятта тоткан роле).*

3. Әсәрнең жанрын, конфликтын, темасын, идеясен табу.

**Укытучы.** “Сүнгән йолдызлар”ның жанрын билгеләп карыйк әле, кем әйтер икән?

*Көтелгән җавап.* Жанры: фаҗигале драма.

**Укытучы.** Драма әсәрләре дип нинди әсәрләргә әйтәбез?

*Көтелгән җавап.* Драма әсәрләре – персонажларның үзара сөйләшүенә корылган әсәрләр. Алар махсус рәвештә сәхнәдә уйнау өчен язылалар.

**Укытучы**. Әсәрнең жанрлары нindиләр?

*Көтелгән җавап.* Драма, трагедия, комедия.

**Укытучы.** Алар нәрсәгә карап жанрларга бүленәләр? Аларның аермасы нидә?

*Көтелгән җавап.* Трагедия - фаҗига белән тәмамланучы әсәр. Комедия -көлкегә корылган әсәр. Драма – үзәгендә кискен конфликт яткан , геройлары авыр кичерешләр белән яшәгән геройларга әйтәләр.

**Укытучы**. Драма әсәрләренең үзенчәлекләрен санап китик.

*Көтелгән җавап.* Эчтәлеге кичерештән гыйбарәт (лирик шигырьгә охшаш). Кичерешләр дәвамлы була, вакыйгалар эчендә ачыла.

**Укытучы**. Хәзер әсәргә якынрак килик. Безгә конфликтын, темасын, идеясен табу өчен, драманың сюжетына анализ ясарга кирәк. Анализ ясаганда, “Сүнгән йолдызлар” спектакленнән өзекләр карап китәрбез.

**Укытучы.** Драма әсәрләре нәрсәгә корыла? Әсәр ничек башланып китә, ягъни конфликтны барлыкка китерүче сәбәпләр нинди? Моны ачыклау өчен безгә әсәрнең экспозиция өлешен табу зарури, кем сөйли?

*Көтелгән җавап.* Әсәрнең беренче өлешендә үк без бер-берсен өзелеп сөюче егет белән кызны очратабыз, Сәрвәр - әбисе тәрбиясендә үскән ятимә кыз, Исмәгыйльнең тормышы тагын да авыррак, ул хәзрәттә хезмәт итә, шуңа күрә гомере буе кимсенеп яши. Муллыкта, бай тормышта яшәгән Надирның да бәхете юк, чөнки тумыштан зәгыйфь, бөкре, ул да чын күңелдән Сәрвәрне сөя, Сәрвәрнең аңа бары тик кызганып каравын гына белгәч, аңа тагын да авыррак, чөнки ул үзен кызгануларын теләми.

**Укытучы.** Шулай итеп, укучылар, әсәрдә өч кешедән торган мәхәббәт өчпочмагы барлыкка килде? Ләкин Исмәгыйль бу мәхәббәттән курка, ни өчен, нинди вакыйга сәбәпче була моңа?

*Көтелгән җавап.* Исмәгыйль куркыныч төш күрә.

**Укытучы.** Бик дөрес, әйдәгез, хәзер шул турыда драмадан өзек карап китик. (Өзек кару)

*Укытучы*. Бу төш, укучылар, нәрсәгә ишарә итә?

*Көтелгән җавап.* Илдә сугыш башлана.

**Укытучы.**Укучылар, тарихны искә төшереп китик әле, XX гасыр башында татар халкына нинди сугышлар, авырлыклар кичерергә туры килә? Әсәрдә сүз кайсы сугыш хакында бара икән?

*Күмелгән җавап:* XX гасыр башы социаль тетрәнүләр, төрле характердагы сугышлар инкыйлаблар, ягъни берсеннән – берсе хәтәррәк, мәрхәмәтсезрәк вакыйгаларга аеруча бай була. 1904 елда Россия Япония белән сугыша. Тагын бер елдан яшәешнең барлык якларын, катламнарын хәрәкәткә китергән Беренче рус инкыйлабы башлана. Аннары илдә кара реакция еллары хөкем сөрә. 1914 нче елда Беренче Бөтендөнья сугышы - характеры ягыннан бүленгән дөньяны бүлү, талау,басып алу сугышы кабына. Әсәрдә шул сугышка бәйле вакыйгалар сурәтләнә. Сугыш гади халыкка кайгы – хәсрәт, ачлык – ялангачлык, рухи һәм физик гариплекләр алып килә.

**Укытучы.** Дөрес,ә кемнәр арасында конфликт туа?

*Күмелгән җавап.* Халык белән җәмгыять арасында конфликт туа. Кешеләр сугышның башлануын теләми. Чөнки ул төрле газаплар китерә.

**Укытучы.** Вакыйга ничек үстерелә?

*Күмелгән җавап.* Бик күпләр сугышка китә. Әмма егетләрнең бер өлеше төрле юллар белән сугыштан кала. Сәрвәрнең дә Исмәгыйльне җибәрәсе килми. Ул им-том итүче Сәрви карчыктан өшкереп ясалган “дару“ юнәлтә. **Укытучы.** Шул урында әсәрнең кульминацион ноктасы барлыкка килә. Нәрсә була?

*Күмелгән җавап.* Сәрвәр үз куллары белән әлеге “даруны“ Исмәгыйльнең колагына сала. Егет үлә.

**Укытучы.** Конфликт ничек чишелә?

*Күмелгән җавап.* Исмәгыйльнең фаҗигале кайгысыннан Сәрвәр юләрләнеп үлә. Надир исә, миңа Сәрвәрдән башка яшәү юк дип, үз-үзенә кул сала. **Укытучы.** Әсәрдәге йолдызлар нинди мәгънә белдерә.

*Күмелгән җавап.* Язмыш, бәхет төшенчәләрен. **Укытучы.** Элек безнең халыкта имеш, күктә һәркемнең үз йолдызы бар дигән ышану яшәгән. Һәрбер йолдыз - кемнеңдер яшәү, бәхет символын белдергән. Шуннан чыгып, без әсәрнең темасын билгели алырбыз. Төп тема нинди булыр?

*Күмелгән җавап.* Кеше бәхете мәсьәләсе. **Укытучы**. Укучылар, әсәрдә тагын берничә ярдәмче тема бар, аларны да билгелик. *Күмелгән җавап.* Мәхәббәт хисенең көчлелеге; социаль тигезсезлек; тормыш гаделсезлеге; кеше бәхетенә киртә булган сугыш афәте.

**Укытучы**. Укучылар, әлеге драма башка әсәрләрдә сирәк очрый торган бер герое белән дә игътибарга лаек. Кем ул?

*Күмелгән җавап.* Надир.

**Укытучы.** Шушы образга характеристика биреп үтик.

*Күмелгән җавап.* Надир - мулла малае. Ямьсез, гарип булса да, ул да кеше, аның да йөрәге бар. Улда ярата. Бу көч аңа ышаныч, яшәргә көч бирә. Сәрвәрнең үлеме Надирның соңгы өметен өзә һәм ул үз-үзенә кул сала.

**Укытучы.** Яшьләр белән Надир арасында ни өчен каршылык килеп чыга? Ни өчен Надир сугыш башлануга куана. Ни өчен аңа юләрләнгән Сәрвәр ныграк ошый?

*Күмелгән җавап.* Укучылар фикере тыңлана. Әсәрдән өзекләр укыла.

**Укытучы**. Шулай итеп, әсәрдә тагын бер ярдәмче тема барлыкка килә, бу нинди тема? Гарип Надирга нинди сыйфат хас?

*Күмелгән җавап.* Аның күңеле матур. Тема: күңел матурлыгы. ***Укытучы***. Укучылар, әсәрдә Исмәгыйльнең төшендә күргән тагын бер символик образ турында әйтелә, нәрсә ул?

*Күмелгән җавап.* Аждаһа. **Укытучы.** Бу образ әсәргә ни өчен кертелгән?

*Күмелгән җавап.* Чөнки сугыш - кешеләрне юк итүче аждаһа. **Укытучы**. Безгә әсәрнең идеясен ачар вакыт җитте, әсәрнең идеясе ничек булыр икән, укучылар?

*Күмелгән җавап.* Матур, якты хыяллар белән яшәүче, бәхеткә тулы хокуклары булган геройларның үлеменә китергән кара көчләргә, сугышка һәм аны башлаучыларга нәфрәт

уяту.
**Укытучы**. Бик дөрес, укучылар, Кәрим Тинчурин әлеге әсәре белән тагын бер кат сугышны - аның илгә китергән фаҗигасен ачып бирде. 4. Дәфтәрләрдә эш. Экранда да күрсәтелә.Сюжеты (аның үсеше, төп сюжет сызыклары). **Сюжет-композициясе** Вакыйгалар “мәхәббәт өчпочмагы”на нигезләнеп алып барыла. Экспозиция – хәзрәттә хезмәт итүче ятим егет Исмәгыйль Сәрвәрне ярата. Әбисе белән генә яшәүче кыз аның мәхәббәтен кабул итә. Мәхдүм Надир, хат язып, Сәрвәрне яратуын белдерә. Төенләнеш – сугыш башлана. Хәрәкәт үстерелеше – егетләрнең бер өлеше төрле юллар белән солдаттан кала, бер төркемен сугышка алып китәләр. Кульминация – Сәрвәр үз куллары белән Исмәгыйльнең колагына “дару”сала. Егет үлә. Чишелеш – Сәрвәр акылдан яза, соңрак сөйгәне кабере өстендә җан бирә. “Соңгы өмете”, “актык йолдызы” булган Сәрвәр үлеменнән соң Надир үз-үзенә кул сала.

5. Образлар системасы. Төп образлар турында сөйләшү, аларга бәя бирү.

**Төп образлар**: **Сәрвәр** – әбисе тәрбиясендә үскән кыз, горур табигатьле, ярдәмчел, кешелекле, әдәпле; бәхетле булачагына ышана, моның өчен бөтенесен эшләргә әзер; кыю, ихтыяр көченә ия. **Исмәгыйль** – тәрбияле, кешелекле, таза, матур, егет; ятимлектә үскән, кимсенеп яши; үзен Сәрвәргә тиң түгел дип саный, ярата белә; Надирга үч сакламый, ихтыярсыз, юаш; кайвакыт мескен булып күренә; “язмыштан узмыш юк” дип саный һәм бәхете өчен көрәшүдән баш тарта. **Надир** – табигать тарафыннан кимсетелгән, бөкре, ямьсез кыяфәтле; бик горур, үзен кызганучыларны дошман күрә; башкалар белән тигез буласы килә; Сәрвәрне яратуы яшәү көче бирә, мәхәббәте тормыш мәгънәсенә әйләнә; Исмәгыйльнең хисләрен хөрмәт итә; хыялында туган бәхетен акылдан язган Сәрвәр белән аралашуда таба; үлеме белән мәхәббәтенең зурлыгын раслый. 6. Әсәрнең сәнгатьчә эшләнеше өстендә эш. - сюжет-композиция төзеклеге; - образ-характерларның гаять уңышлы эшләнеше; - вакыйга-күренешләрнең үзара тыгыз бәйләнештә төп идеяне ачуга хезмәт итүе; - музыкаль жанрда булуы;
- халык иҗатын, тапкыр гыйбарәләрне, мәкаль-әйтемнәрне оста файдалануы; - лиризм һәм трагизмның үрелеп баруы; - геройларның рухи дөньясын ачу өчен, психологизм алымнарына мөрәҗәгать итүе.

7. Әсәр исеме өстендә эш, авторның әйтәсе килгән фикерен билгеләү.

**Укытучы.** Укучылар, драманың исемен автор ник “Сүнгән йолдызлар” дип атады икән? Әсәрнең исемендә нинди мәгънә булырга мөмкин?

*Көтелгән җавап.* Драма Исмәгыйльнең төш күрүе белән башланып китә. Төш әсәрдә күчерелмә мәгънәгә ия һәм мөстәкыйль сюжет сызыгын тәшкил итә. Төштә аждаһаның йолдызларны сүндерүе, Исмәгыйльнең, Сәрвәрнең, Надирның һәм башка бик күп егетләрнең йолдызлары сүнүе, күк йөзен караңгылык каплап алу драманың төп сюжет сызыгында булачак күңелсез вакыйгаларга ишарә булып тора. Шул рәвешле, әсәр үзәгенә драматург халык иҗатындагы ышануны ала.

**Укытучы.** «Сүнгән йолдызлар - солдатка алынучылар гына түгел. Ләкин Исмәгыйль төшен сөйләгәндә, йолдызларның исемнәрен үк әйтә. Үзен, Сәрвәрне, Надирны һәм тагын берничә дустын атый. Ләкин ни өчен Исмәгыйль дә, Сәрвәр дә, Надир да йолдызлар икән? Йолдызлар сүнү аларның үлемеме?

*Көтелгән җавап.* Исмәгыйль үлгәннән соң, Сәрвәрнең бәхете сүнә. Ә Сәрвәр үлгәч, Надирның бәхете сүнә. Исмәгыйль Фәрхи карчык даруыннан үлә, ләкин ул да даруны бәхетсезлеге аркасында салдырырга риза була — сугышка китсә, кайта алмавын белә, Сәрвәрне бервакытта да күрә алмам дип хәсрәтләнә.

**Укытучы.** Димәк, укучылар, әсәр ни өчен “ Сүнгән йолдызлар “ дип атала ?

*Көтелгән җавап.* Сүнгән йолдызлар — кешеләрнең сүнгән бәхетләре.

**Укытучы.** Ә бәхетсезлекнең сәбәбе нәрсәдә?

*Көтелгән җавап.* Автор сурәтләвенчә, кешеләрнең бәхетсезлеге — аларның гаепләре түгел, ә тормыш гаделсезлеге. 1914 елгы сугыш та, Надирның ямьсезлеге, гариплеге дә тормыш гаделсезлеге һәм кешеләр ул гаделсезлекне үзләре генә җиңеп чыга алмыйлар.

Исмәгыйль белән Сәрвәр аңа каршы үзләренчә көрәшәләр, язмышны хәйлә белән җиңмәкче булалар, ләкин җиңеләләр. Надир бу гаделсезлекне үзенчә җиңә. Бу әсәрдә ул — бердәнбер көрәшче.

**IV. Йомгаклау. Нәтиҗә.**

**Укытучы.** Әсәрдә нинди проблема күтәрелгән?

*Көтелгән җавап.* Пьесада мәхәббәт хисенең матурлыгы, кеше хокукы, аның язмышы; кеше бәхетенә киртә булган сугыш афәте, тормыш гаделсезлеге проблемалары күтәрелгән.

**Укытучы.**Без нинди сорауга җавап эзләдек соң?

*Көтелгән җавап.* «Бәхетле булыр өчен нишләргә кирәк соң?» дигән сорауга җавап эзләдек.

**Укытучы.** Төп тема булып нәрсә чыга?

*Көтелгән җавап.* Әсәрнең төп темасы — кеше бәхете.

**Укытучы.** Әйе, тема пьесаның баштагы күренешендә үк калкып чыга. Исмәгыйль үзен көткән бәхеткә икеләнеп карый, Сәрвәр исә бәхетле тормышын бик ачык күз алдына китерә, Надир үз бәхетен мәхәббәтендә эзли. Хәтта Фәрхи карчыкның да үз бәхете бар. Фәрхи карчыкның баю ягын гына кайгырта. Димәк, әсәрдәге һәр конфликтлы вакыйгада бәхет темасы төрле каршылыкка очрый. Ачылганнан-ачыла бара. Ахыр чиктә проблемага— «Бәхетле булыр өчен ни эшләргә кирәк?» дигән сорауга әйләнә. Бу яктан пьеса чәчмә әсәрләргә охшый.

Әсәрнең төп герое — Надир, дидек. Әсәрнең күп өлеше аның кичерешләрен ачуга багышлана. Надир кичерешләрен, лирик әсәрләрдәге кебек, өчкә бүлә алабыз. Хисенең дәрәҗәсе, сәбәпләре һәм юануы.

Әсәрнең төп темасы — кеше бәхете, дидек. Бу тема бүгенге көндә дә актуаль. Шуңа да ул театр сәхнәләрендә уңышлар белән бара.Хәтта Әнкара дәүләт театрында Кәрим Тинчурин пьесасы буенча "Сүнгән йолдызлар" премьерасы булды . Татар милләтен бөтен дөньяга таныту , сәнгатебезне, мәдәниятебезне чит илләрдә күрсәтү, әлбәттә, зур дәрәҗә. Без Кәрим Тинчурин белән горурланабыз!

2. Билгеләр кую.

3. Өй эше. 1.Төп образларга характеристика язарга. (Үрнәк бирелә.)
2. Инша язу өчен материал тупларга.

## МИН УКЫТУЧЫЛАР НӘСЕЛӘННӘН

*Кирушин Виталий Климентович, 9 класс*
*Фәнни җитәкче - Кирушина Елизавета Васильевна,*
*Мамадыш районы МБГБУ«Албай төп гомуми белем мәктәбе"*

Укытучы! Бар нәрсәнең, һәр эшнең башлангычы син. Укытучы булу – чын батырлык. Укытучы үзенә игелеклелек хисләрен, сабырлыкны, тыйнаклыкны, гадилек һәм олылыкны җыйган. Кешелек яши башлаганнан бирле остаз –укытучы булган.

Җир йөзендә яшәгән һәр кешенең язмышы укытучыга бәйле. Тормышта бар яктылык аңардан – хакыйкатькә, зирәклеккә, туганлыкка, яхшылыкка, тынычлыкка хезмәт иткән укытучыдан башлана.

Әйе, укытучы-иң изге, иң гүзәл зат. Безгә саекмас белем чишмәсе, тәрбия бирүче ул.

Минем нәселем - укытучы-мөгаллимнәр нәселе. Ул-минем горурлыгым, чөнки әби-бабам, апа - абыйларым,туганнарым, әти-әнием үзләренең бөтен гомерләрен белем бирүгә багышлаган күркәм затлар. Алар, мәктәп тормышын шәхси тормыштан өстен куеп, бар вакытларын яшь буынга тыйнак кына изгелек орлыкларын чәчүгә, гыйлем таратуга багышлый. Бу һөнәрнең бөеклеген аңлаганга, мин дә киләчәктә нәселемнең династиясен дәвам итеп укытучы булырга хыялланам.

Укытучы эше җиңел түгел икәнен күреп беләм. Алар бар белгән белемнәрен балаларга бирүчеләр, укучыларны кызыксындырган барлык сорауларга җавап табучылар, һәр көнне күз нурларын түгеп дәфтәр тикшерүчеләр дә.

Дәреслектән тыш, төрле мәгълүмат чыганакларын, информацион технологияләрне кулланып, кызыклы дәресләр үткәрүче укытучы булу өчен бик күп сыйфатларга ия булырга кирәк. Алар – белемле дә, акыллы да, сабыр –түземле дә, гүзәл дә. Укытучы булу өчен иң кирәкле сыйфат – балаларны ярату, аларны бертигез күрү. Бу һөнәр зур сабырлык, түземлек, күпкырлы белем, зыялылык, балаларга карата олы мәхәббәт һәм сайлаган эшеңә чиксез бирелгәнлек таләп итә.

”Укытучы” сүзе чыннан да изге, матур исем. Укытучы хезмәте авыр да, җаваплы да, кызыклы да. Бу һөнәрне сайлау тынгысызлык, эзләнү юлын сайлау, үз – үзеңә искиткеч таләпчән булу, көндәлек тырыш, эзлекле хезмәт юлын сайлау дигән сүз.

Минем туганнарым шул сыйфатларның барына да ия дип уйлыйм.

Эшемнең **максаты**: нәселебездәге укытучыларны барлау, үзебезнең укытучылар династиясенең нәсел шәҗәрәсен төзү.

**Бурычлары:** мәгърифәтчелек тарихы турында тулырак мәгълүмат алу, укытучы хезмәте белән якыннанрак танышу, туганлык җепләрен ныгыту.

Фәнни-эзләнү эшемне башлап җибәрү белән кызыксыну туды. Кеше үз нәселен, аларның кемнәр, нинди һөнәр ияләре булулары турында беләләрме? -дигән сорауга җавап эзләп, мин авылым халкыннан сорашу үткәрдем. Ул түбәндәге сораулардан торды.

1. Син үз нәселеңне беләсеңме?

- әйе, беләм -47% , -юк - 28%, -кызыксынам -19%

2.Сезнең нәселдә нинди һәнәр ияләре булган?

- укытучылар - 21% - гади эшчеләр - 32% -төрлесеннән - 47%

3.Син үзең нәсел шәҗәрәсен булдырыр идеңме?

- әйе - 35%

-белергә телим, эшне башладым - 38% уйланам - 27%

### *1.Мәгърифәтчелек тарихы*

Безнең төрки бабаларыбыз IV гасырда ук укый – яза белгәннәр . Идел буе Болгар дәүләте чорында мәгърифәт эше аеруча алга киткән .Чөнки гыйлем һәрвакыт игьтибар үзәгендә булган, уку йортлары тоту изге эш дип саналган. Мөселманнарның һәр мәчете каршында мәдрәсә булган. Әлбәттә инде , бу мәдрәсәләрнең төп юнәлеше – дини белем бирү , мәдрәсә программасына Коръәнне үзләштерү һәм ятлау, аның тәфсирен, хәдисләрне, шәригатьне һәм гарәп телен өйрәнү кертелгән, аларда белем бирү югары булмый . Әмма халкыбызның мәгърифәтенә нигез салу шулардан башланган. Казан ханлыгында иң зур уку йортларының берсе сәед Кол Шәриф мәдрәсәсе булган. Биредә үзенең диненә һәм ватанына чын күңелдән бирелгән шәкертләр тәрбияләнгән. Аларның барысы да 1552 елда Казанны урыс гаскәрләреннән саклаганда һәлак булганнар.

Патша хөкүмәте ,Казанны сугышып алганнан соң , татар мәчетләре белән бергә алар янындагы мәдрәсәләрне юкка чыгарырга тырышкан .18 нче йөзнең 70 нче елларыннан башлап , мәдрәсәләрнең хәле шактый җиңеләйгән.(Пугачев восстаниясенә бәйле, татар һәм башка милләтләрнең зур көч булып күтәрелүе хөкүмәтне уйланырга мәҗбүр итә.) Ул чорда Казанда ике уку йорты - Ахун һәм Апанай мәдрәсәләре, 1780 елда Әмирхания мәдрәсәсе ачыла.

XVIII гасыр ахырында атаклы авыл мәдрәсәләре оеша башлый. Кышкар, Мәнгәр, Сатыш, Саба, Бәрәскә, Эстәрлебаш, Мәчкәрә, Тайсуган, Ташкичү авылы мәдрәсәләре шундыйлардан. 20 нче гасыр башында мәгарифнең дөньявилыгын үстерү юнәлешендә эш башлана.Шул нигездә хәреф- иҗек ысулына корылган кадими мәдрәсәләргә аваз-хәреф ысулына нгезләнгән җәдиди мәдрәсәләр өстәлә . Шәкертләргә күбрәк дөньяви белемнәр бирүне максат итеп куйган яңа тип мәдрәсәләрдән “Мөхәммәдия”

,”Касыймия”,”Галия”,”Хөсәения”,”Рәсүлия”,”Буби”ны әйтеп үтәргә кирәк. Татарның үткәндәге күпчелек күренекле шәхесләре дә нәкъ менә шушы мәдрәсәләрдән чыккан .

Кыскасы , бездә гасырлар дәвамында төрле кысуларга һәм югалтуларга карамастан, аң-белемгә игътибар зур булган, татарлар революциягә кадәр үк гыйлемле халыкларның берсе саналган .

***2.Кем ул укытучы?***

Без укытучы һөнәрен игенче һөнәре белән чагыштырыр идек, чөнки игенче зур авырлык белән иген үстерә. Укытучы да нәни баланың күңеленә яхшылык орлыгы чәчә, белем бирә, тәрбияли.

**Һөнәрләр күп: кем булсаң да**
**Табиб, эшче, тукучы...**
**Тик онытма бер нәрсәне –**
**Юл күрсәтә укытучы.**
**Бала күңеленә белем белән**
**Бәхет орлыклары саласың.**
**Кешеләргә бәхет бирсәң генә,**
**Син бәхетле була аласың –**
**Укытучы була аласың!**

Кеше - кеше өчен кыйммәтле дару ул, дигән борынгылар. Табиблар кешене дару белән дәвалыйлар. Ә укытучы хезмәтендә әзер таблеткалар юк. Һәр очрак өчен, һәр укучы өчен укытучылар шул "таблеткалар”ны табарга тиеш. Педагогның шәхси үрнәге, сүзе, киңәше – укучы балалар өчен алыштыргысыз бер дару.

Шундый гыйбрәтле риваять яшәп килә. Кешеләр авыр йөк ташый. Ул йөк күтәрергә уңайлы һәм уңайсыз булган төрле зурлыктагы капчыкларга тутырылган була. Һәр эшче, үзенә уңайлырак капчык сайлап алып, аны тиешле урынга илтеп куя һәм, тагын шундый ук капчык сайлау өчен, кире шул урынга әйләнеп кайта. Бары тик бер эшче генә һәрвакыт, уфылдый-уфылдый, җилкәсенә иң авыр йөкне сала һәм аны урынына илтеп җиткерә. Ә инде аннан: "Ни өчен син үз теләгең белән иң авыр йөкне аласың?”- дип сорагач, ул: "Аны кемдер күтәрергә тиеш иде. Әйдә, ул кеше мин булыйм,” –дип җавап бирә. Әйе,чынлап та,укытучы ул - дөньядагы иң авыр йөкне күтәрүче.

**3.Укытучылар нәселе**

Һәр кеше дә укытучы була аламы? Минемчә, укытучы булып туарга кирәк. Укытучы һөнәрен сайлау- тынгысызлык,эзләнү юлын сайлау, үз-үзеңә искиткеч таләпчән булу, тырыш хезмәт юлын сайлау дигән сүз. Укытучы һөнәрен сайлаган кешегә иң башта-табигать биргән сәләт, тирән белем, сабырлык, күркәм холык, һәрвакыт үз-үзннне башкаларга үрнәк итеп тота белү сыйфаты хас булырга тиеш. Мин моны ишетеп кенә түгел, күреп тә беләм, чөнки нәселебездә безнең укытучылар бик күп. **Бабам - Кирушин Михаил Григорьевич, әбием – Анна Ивановна** Казан дәүләт педагогия институтын тәмамалыйлар, тарихчылар бабамның бертуганы - **Роза Григорьевна** гомере буе “Усали урта мәктәбе”ндә татар теле һәм әдәбияты, ә тормыш иптәше **СеменПасыев** музыка укытучысы, оста гармунчы. Аның кызы - **Лидия Пасыева** шул ук мәктәптә тарих улы- **Владимир Пасыев** - географ, әбием белән бертуган – **Ольга Ивановна**- бология укытучысы ,аның улы - **Артем Михайлович**-географ, киленнәре - **Светлана Владимировна** - чит телләр, әби - бабамның кызлары - **Людмила Михайловна** -тарих, **Любовь Михайловна** - туган тел һәм әдәбияты ,аның тормыш иптәше **Геннадий Алексеевич** - информатика, аларның уллары - **Владимир Геннадьевич** - физика ,математика һәм кызлары **Ульяна Геннадьевна** - тарих, әби-бабамның улы - **Леонид Михайлович химия һәм биология**, аның хатыны **Нина Павловна** - математика һәм минем әтием **Климент Михайлович -** химия, биология һәм әнием - **Елизавета Васильевна -** туган тел һәм әдәбияты укутычсы. Шуларның берничәсе турында таныштырып китәсем килә.

Авылым тарихында якты йолдыз булып кабынган, халкыбыз хәтерендә мәңге уелып калган онытылмас затларыбыз байтак.Шуларның берсе – **бабам - Кирушин Михаил Григорьевич.** Мин аны яхшы хәтерлим, чөнки мин аның матур әкиятләрен тыңлап үстем.

Аның исеме күпләргә таныштыр дип уйлыйм, чөнки бабам 30 елдан артык мәктәптә балалар укыткан.

“Үзеңнән соң җирдә мәңгелек эз калдырыйм дисәң- укытучы бул!”. Хак сүзләр. Укытучыдан башка президент та, патша да, инҗенер- төзүче, язучы, сатучы да булмас иде. Балаларның иңнәренә канат куеп, һәрберсенә тормышта урын табарга булышкан кеше дә укытучы!” дип үзенең төпле киңәшләрен бирде бабабыз.

Аны искә алмаган бер генә көнем дә юктыр. Ул чын тарихчы иде. Үз һөнәрен бик яратып башкарды. Укыткан укучыларыннан да шундый ук сүзләрне ишетеп үсәм.

Укытучы бөек, изге була
Йөрәкләрдә мәңге саклана.

Үз гомерен, нәкъ бабам кебек, шул һөнәргә багышлаган әбием - **Кирушина Анна Ивановна** турында да таныштырып китәсем килә. Ул бүгенге көндә дә исән-сау, безнең белән бергә яши.Әбием дә тарих укытучысы. Алар бабам белән бергә Казан педагогия университетын тәмамлыйлар. Гомерләре буе икесе дә бер сукмактан атлыйлар.

“Ул вакытта авыл мәктәпләрендә дә балалар бик күп. Һәрберсенә тиешенчә белем бирү өчен бик тырышырга туры килде.Хезмәтем минем- мәңге картаймас шатлыгым чыганагы” – дип сөйли әбием.

Әбием белән бабам эшләгән ватытта һәр эшне җиренә җиткереп башкаручылар булганнар. Авылыбызның музее да алар инициативасы һәм хезмәте белән сафка баскан. Ул вакытта компьютерлар юк, әбием мәгълүмат тупласа, бабам аны үзенең матур итеп язуы белән стендлар ясаган. Бу хезмәтне күрмәгән, бәяләмәгән кеше юктыр.Эшне яратып, тырышып эшләгәндә генә менә шундый нәтиҗәләргә ирешеп була.

Алар үз гомерләрен укытучы хезмәтенә багышлаганнар. Балаларына да бу һөнәргә мәхәббәт тәрбияләгәннәр. Мин бу сүзләрне бик зур горурлык хисе белән әйтә алам. Чөнки дүрт баланың өчесе укытучы һөнәрен сайлаганнар. Әби-бабамның зур кызы - **Людмила Михайловна**-тарих, аннан кечесе - **Любовь Михайловна** - татар теле һә әдәбияты, ә кече уллары ,минем әтием - **Климент Михайлович** химия һәм биология фәне укытучысы булу өчен югары белем алганнар.

Сиңа сөйләрләр- онытырсың, эшләп күрсәтерләр- хәтереңдә калыр.
Үзең эшләп карасаң- аңларсың...

**Минем әтием - Кирушин Климент Михайлович**- мәктәбебездә директор булып эшли һәм бер үк вакытта балаларга белем бирә.

Хөрмәтле әтием! Синең өчен
Шигъри юллар килә күңелгә,
Керсез уйлар бөреләнә җанда,
Йөрәкләрдән моңнар түгелә.
Синең күзләр җылы караш сирпи
Якты нурлар бизи кыйбланы.
Кадерле әтием! Син - кояшы
Мәктәп дигән нәни дөньяның.
Олы җанлы укытучы исемен
Син йөртәсең горур, хөрмәтләп.
Синең исем белән мактаулы һәм
Синең исем белән хөр мәктәп!
Киң карашлы укытучы да син,
Таянычы һәрбер баланың,
Киләчәктә гөлчәчәккә күмелер
Син эз салган мәктәп аланы.
Синең сүзең иң саф чишмә кебек
Шифа бирә һәркем аңына,
Мәрхәмәт һәм шәфкать йөге белән
Тумыштан ук сеңгән канына.

Киң күңелле һәм ярдәмчел дә син -

Җитәкчегә тәңгәл сыйфатлар.

Әтием хезмәт блын химия һәм биология укыту белән башласа, хәзерге көндә ул баларга физик тәрбия бирә. Спортны чын күңелдән үзе яратканга , бездә дә шуны тәрбияли. Мәктәбебездә укучылар физкультура дәресләрен түземсезлек белән көтеп алабыз. Дәресләрдән тыш җиңел атлетика һәм чаңгы белән өстәмә шөгыльләнәбез. Эшнең нәтиҗәле булуы әтиемне дә, безне дә бик сөендерә. Районыбызда бу төр спорт буенча без һәрвакыт беренчеләр. Республика күләмендә уздырылган ярышларда да актив катнашып урыннар яулыйбыз.

Әтием тырыш хезмәте өчен районыбызның мактау грамоталары,Россиянең мактау грамотасы белән бүләкләнә.

Инде әтием белән бер сукмактан атлаучы - **әнием – Кирушина Елизавета Васильевна** турында да әйтеп китәсем килә. Ул татар теле һәм әдәбияты укытучысы. Әниемнең үзенең кечкенә вакытларын искә алганда, “Без иптәш кызларым белән гел укытучы уенын уйдык идек” дип искә ала.Шуңададыр бу хезмәт юлын ул бер икеләнүсез сайлый һәм үз эшен бик яратып башкара. “Укучыларыңны бер төн эчедә сагынып киләсең икән, бу хезмәт юлын сайлап ,син ялгышмаганлыгыңны аңлыйсың”-ди әнием. Укучылар белән төрле конкурсларда катнашалар, район олимпиадаларында призлы урыннарны яулыйлар.

Инде әби -бабамның балалары укутучы һөнәрен сайлаган кебек, яңа буын алмашуын күрәм. Без әти-әниемнә ике бала. Апам - **Кирушина Ираида Климентовна** да үзе теләп укытучы һөнәрен сайларга теләде. Ул бүгенге көндә Казан дәүләт федераль университетының Алабуга филиалында чит телләр буенча белем ала. “Уку тырышып укыган кешегә авыр түгел,узмне чын укытучы итеп дәрес биргәндә тоям “-ди апам. Иптәшләре дә аның турында болай диләр:”Укытучы булу сезнең каныгыздан күчеп килә, шуңа күрә дә һәр башкарыласы эш сиңа җиңел бирелә”. Уку йортында үткәрелгән чараларда да актив катнаша ул. Һәм эшенең нәтиҗәләре дә бар.

Минем дә теләгем - укытучы булу. Мина бу теләк әтимнән күчкән дип уйлыйм. Чөнки әтием безнең белән сәламәт яшәү рәвеше алып бара. Сәламәт кеше генә дөрес уйлый, фикерли ала ди ул. Бу фикер белән мин дә килешәм. Шуңададыр алдагы тормышымда теләгем- физик тәрбия укытучысы булу. Тырышып уку белән бергә бик күп ярышларда да катнашам. Теләп, яратып башкарылган эшнең нәтиҗәсе дә була.Район, республика күләмендә оештырыл-

ган ярышларда призлы урыннары бик күп.

**Йомгаклау**

Эшемне тәгәлләгәч, үзебезнең нәселдә булган укытучыларны болындагы матур чәчәкләр итеп күз алдына китердем. Шуңа күрә дә үзебезнең нәсел мөгаллимнәре шәҗәрәсен чәчәк болынында ясадым. . Чыннан да, буыннар алмаша бара. Әби-бабам һөнәре әти-әниемә, алардан безгә күчә . Бу хезмәт юлын сайлаучылар чын мәгънәсендә бөек кешеләр. Чөнки укытучының хезмәт нәтиҗәсе- аның укучыларында. Әбиемнең безгә-оныкларга һәрвакыт мисал итеп әйтә торган Муса Җәлилнең “Бер үгет” шигыреннән өзек китерәсем килә.

Син яшәмә җирдә файдасыз бер

Түмгәк булып тигез урында.

Янып калсын гомерең, маяк булып

Үзеңнән соң килгән буынга.

Күренекле язучы Фәнис Яруллин укытучыларга юкка гына “Се иң гүзәл кеше икәнсез!” – дип әйтмәгән. Чыннан да, кирәк чакта безне мактаучы да, яклаучы да, киңәшче дә – укытучылар. Нәсебездә булган укытучыларга, җир йөзендәге барлык укытучыларга узем һәм барлык укучылар исеменнән рәхмәт әйтеп, шушы шигъри юллар белән чыгышымны тәгәллисем килә.

**Җир йөзендә иә-иң матур теләкләрне,**

**Сорасалар, багышларга кемгә, диеп.**

**Әсир иткән үзенә бик күп йөрәкләрне**

**Укытучыма, дияр идем, башым иеп.**
(Лена Шагыйрьҗан)

*Кулланылган әдәбият*
1. Г.Гарипова, Н.Гариф “Биектау авылы тарихы”, Казан -2016.
2. Р.Гыйлемханов “Биектау авылы тарихы”, Казан – 2016.
3. Балык Бистәсе районы, Биектау авылының “Туган як ”музее чыганаклары.
4. Балык Бистәсе районы, Котлы – Бүкәш авылы музее чыганаклары.
5. Р.Гыйлемханов, Н.Гариф “Биектау авылы мәктәбенә бәйле сәхифәләр”, Казан -2017.

## ФОРМИРОВАНИЕ БЕЗОПАСНОГО ПОВЕДЕНИЯ МЛАДШИХ ШКОЛЬНИКОВ НА ДОРОГАХ С УЧЕТОМ ТРЕБОВАНИЙ ФГОС

*Латипова Лилия Фаизовна,*
*воспитатель группы продленного дня*
*МБОУ КСШ №3 г. Кукмор РТ*

### 1. Введение

Жизнь, здоровье и безопасность детей полностью зависит от окружающих его взрослых. Опыт развивающихся стран, раньше нас вступивших в автомобильный век, показывает, что обучать ребенка правильно переходить улицу надо с самых ранних лет. Не с пяти – шести, как принято у нас, а гораздо раньше, так как знания, полученные в детстве наиболее прочны, а правила усвоенные в эти годы, впоследствии становятся нормой поведения, а соблюдение – потребностью человека.

Обучение младших школьников культуре поведения на улице тесно связано с развитием у детей ориентировки в пространстве. Кроме того, каждый педагог должен помнить, что нельзя воспитать дисциплинированного пешехода, если с детства не прививать также важные качества, как внимание, собранность, ответственность, осторожность, уверенность. Отсутствие этих качеств может быть причиной дорожных происшествий.

В совершенствовании и закреплении знаний особая роль отводится организации игровой деятельности детей, в которой формируется пространственная ориентация школьников и их умение применять эти знания на практике.

Проект по подготовке младших школьников к безопасному поведению на дорогах разработан в рамках Федерального закона «О безопасности дорожного движения», закона Российской Федерации «О безопасности», «Правил безопасного поведения учащихся на улицах и дорогах», Федерального государственного стандарта начального общего образования.

В современной системе школьного воспитания остро обозначилась проблема кардинального изменения ее содержания, форм и методов организации работы по обеспечению безопасности школьников в дорожно - транспортной среде.

Осознание этого привело нас к необходимости создания проекта направленного на внедрение систематической разноплановой работы, использование творческих форм и методов обучения и воспитания детей, а так же активные формы организации обучения педагогов, просвещения родителей по данной проблеме.

Данный проект написан для учащихся начальных классов, который позволит сформировать у детей устойчивый навык переключения на самоконтроль (умение пользоваться знаниями и следить за своим поведением) в окружающей дорожно-транспортной среде на дорогах.

## 2. Актуальность проекта

При переходе на федеральные государственные стандарты второго поколения, современные требования к образованию предусматривают необходимость сконцентрировать своё внимание на соблюдении безопасного поведения младших школьников на дорогах.

В наши дни все большее место в системе безопасности жизнедеятельности занимает детский дорожно-транспортный травматизм, что доказано показателями статистических данных.

В прошлом году на дорогах Татарстана погибло 26 детей, это на 2 ребенка больше, чем в 2012-м. Число погибших в ДТП детей в РТ выросло на 8,3%. Число раненных детей увеличилось на 3,9%: с 611 человек до 635.Общее число аварий с участием детей выросло на 5,2%. В 2012 году было зарегистрировано 573 ДТП, в 2013-м – 603.

*За 7 месяцев 2013 года на улицах городов и дорогах Республики Татарстан было зарегистрировано 328 ДТП с участием детей, в которых 15 детей погибли и 339 детей получили травмы различной степени тяжести.*

В возникновении повреждений наряду с анатомо-физиологическими и психологическими особенностями детей существенное значение имеет, и незнание детьми правил поведения на дороге и в общественных местах, недостаточность житейских навыков, повышенная детская любознательность, растерянность и страх в чрезвычайных ситуациях, неумение выйти из сложной ситуации, в которой он оказался.

В современном обществе родители чаще всего обеспокоены своим материальным благосостоянием и все меньше уделяют внимание вопросам безопасности своих детей, хотя многие родители оберегают и защищают своего ребенка от опасности. Но задача взрослых должна состоять не только в этом, а в том, чтобы подготовить детей к встрече с различными сложными, а порой опасными ситуациями.

Поэтому от воспитателя группы продленного дня требуется не столько обучение школьников правилам дорожного движения, сколько формирование у них навыков безопасного поведения и развитие познавательных процессов, необходимых для правильной ориентации на улице. Исходя из этого, нами был выбран проект «Формирование безопасного поведения младших школьников на дорогах с учетом требований ФГОС».

## 3. Цель и задачи проекта

**Цель проекта**: Формирование навыков безопасного поведения младших школьников на дорогах, с целью предупреждения детского дорожно-транспортного травматизма с учетом требований ФГОС.

**Задачи проекта:**

1. Обучение младших школьников правилам безопасного поведения на дорогах.
2. Формирование сознательного отношения младших школьников к выполнению правил дорожного движения, ценностного отношения к своему здоровью.
3. Воспитание чувства ответственности за личную безопасность.
4. Развитие самостоятельности, активности, мотивацию к безопасному поведению.

**Целевая группа проекта**: учащиеся начальных классов

### 3.1. Объект исследования

Внеурочная деятельность с младшими школьниками в образовательном учреждении в соответствии с требованиями ФГОС.

### 3.2. Предмет исследования

Формирование навыков безопасного поведения младших школьников в процессе внеурочной деятельности.

## 4. Проектное решение

**1 этап. Подготовительный.**

Подготовительная работа с учащимися.

Педагог создает в группе проблемные ситуации, планирует развивающие вопросы, которые можно задавать в любое время, получив первичную информацию о базовом запасе

знаний, представлений детей по теме педагог, получает информацию того, какой они видят свою деятельность, кто из детей нуждается в поддержке, помощи, делает выводы и намечает формы предстоящей работы. Часть учащихся получают задание по выбранной теме.

Подготовительная работа с родителями.

Перед началом работы над проектом педагог рассказывает родителям о целях, задачах проекта, старается убедить их в необходимости оказания помощи и серьезного отношения к исследованиям, заданиям и играм детей. К сожалению, далеко не все родители понимают необходимость воспитания поведения на улицах. Однако работа в рамках проекта оказывается привлекательной для многих родителей, сближает их с детьми.

Материал для проведения проекта:

Книги, настольные игры, альбомы, листы бумаги, карандаши, фломастеры, линейка, восковые мелки, иллюстрации, плакаты, цветная бумага, конструкторы различных видов, наборы дорожных знаков, модели транспорта, настольные игры, художественная литература, картотека со стихами, загадками, пословицами, для ролевых игр вещи, для переодевания, наборы с медицинскими инструментами, руль, жезл и пр.

**2 этап. Основной**.

Выявив объем знаний детей, их интересы и пожелания, мы разработали программу внеурочной деятельности по правилам дорожного движения.

На мероприятиях младшие школьники выступали со своими сообщениями, приготовленными дома совместно со своими родителями. Такие выступления перед сверстниками развивали у детей познавательные и творческие способности, уверенность в своих возможностях, умение объяснять и отстаивать свою точку зрения, умение задавать и отвечать на вопросы. У детей повысилось самооценка, появилось стремление к дальнейшему познанию окружающей действительности.

Воспитатели проводили ряд мероприятий, в которых дети узнали много интересного о правилах безопасного поведения на дорогах, научились ориентироваться в различных жизненных ситуациях и применять знания, умения и навыки в повседневной жизни.

Таким образом, участвуя, во внеклассных мероприятиях младшие школьники:

- самостоятельно адекватно оценивают правильность своего решения в любой жизненной ситуации
- эмоционально настраиваются на предстоящую деятельность
- учатся ставить цели
- развивают коммуникативные компетенции
- развивают в себе чувство собственной значимости и инициативности
- ощущают проявления заинтересованности, не безразличия, заботы со стороны сверстников и взрослых.

**3 этап. Заключительный**.

На третьем этапе подводятся итоги проекта в виде:

- сюжетных игр с викториной
- тестирование
- экскурсии
- видео уроки и т. п.

## 5. Жизненный цикл и этапы реализации проекта

**Сроки реализации проекта** – 2017 -2018 г.

**Этапы реализации проекта:**

**1.Подготовительный этап** (02.09.2017 г.-11.11. 2017 г.)

**2.Основной этап** (15.11.2017- 25.03.2018 г.)

**3.Заключительный этап** (13.04.2018- 24.05.2018г.)

**Программа проектных мероприятий**

| | Комплекс мер | Место проведения | Срок проведения | Ответственный |
|---|---|---|---|---|
| **Этап 1** | | | | |
| | Игра «Юные инспекторы дорожного движения»: «Понятие об участниках дорожного движения». | Кабинет начальных классов | 02.09.2017 | Латипова Л.Ф. |
| | Встреча сотрудников УГИБДД МВД с родителями школьников | Актовый зал | 16.09.2017 | Завуч по УВР |
| | Родительское собрание на тему «Дети и ПДД» | Актовый зал школы | 27.09.2017 | Латипова Л.Ф. |
| | Конкурс рисунков «Я и дорога» | Кабинет ГПД | 09.10.2017 | Латипова Л.Ф. |
| | Беседа « Где можно кататься на санках и коньках?» | Кабинет ГПД | 25.10.2017 | Латипова Л.Ф |
| | Конкурс рисунков «Осторожно скользко!» | Кабинет ГПД | 30.10.2017 | Латипова Л.Ф |
| | Беседа «Уважай правила движения!» | Актовый зал | 11.11.2017 | Латипова Л.Ф. |
| **Этап 2** | | | | |
| | Игра «Где играть?» | Кабинет ГПД | 15.11.2017 | Латипова Л.Ф. |
| | Мероприятие «Посвящение в пешеходы». | Кабинет начальных классов | 07.12.2017 | Латипова Л.Ф. |
| | Веселые старты «Светофорик» | Спортплощадка | 10.12.2017 | Латипова Л.Ф. |
| | Игра « Мы учимся соблюдать правила дорожного движения» | Кабинет начальных классов | 19.12.2017 | Латипова Л.Ф. |
| | Игра «Юные инспекторы дорожного движения»: «Уважайте правила движения» | Кабинет ГПД | 25.12.2017 | Латипова Л.Ф. |
| | Мероприятие «Улица полна неожиданностей» | Актовый зал | 05.01.2018 | Латипова Л.Ф. |
| | Весёлые старты «Мир на дороге» | Спортплощадка | 17.01.2018 | Латипова Л.Ф. |
| | Игра «Внимание улица» | Кабинет ГПД | 30.01.2018 | Латипова Л.Ф. |
| | Беседа сотрудников УГИБДД с школьниками. | Актовый зал | 15.02.2018 | Завуч по УВР |
| 0 | Игра «Азбуку дорожную - знать каждому положено» | Кабинет начальных классов | 21.02.2018 | Латипова Л.Ф. |
| | Игра «Дорожная | Кабинет ГПД | 18.03.20 | Латипова Л.Ф. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 1 | азбука» | | 18 | |
| 2 | Игра «Безопасное колесо» | Спортплощадка | 25.03.2018 | Латипова Л.Ф. |
| **Этап 3** | | | | |
| | Викторина «Юные инспекторы дорожного движения»: «Внимание улица» | Кабинет ГПД | 13.04.2018 | Латипова Л.Ф. |
| | Сказка «Путешествие в страну дорожных знаков» | Кабинет начальных классов | 17.04.2018 | Латипова Л.Ф. |
| | Тест «Дорожные знаки», по правилам дорожного движения. | Кабинет ГПД | 07.05.2018 | Латипова Л.Ф. |
| | Викторина « Юные инспекторы дорожного движения»: «Какой я пешеход?» | Кабинет ГПД | 10.05.2018 | Латипова Л.Ф. |
| | КВН: « Мы пешеходы» | Спортзал | 13.05.2018 | Воспитатели ГПД |
| | Мультфильм «Пешеходный переход» | Актовый зал | 15.05.2018 | Воспитатели ГПД |
| | Экскурсии «Я–пешеход» | Стадион | 17.05.2018 | Воспитатели ГПД |
| | Изготовление буклетов и памяток | Кабинет ГПД | 20.05.2018 | Давлетшина Л.М. |
| | Викторина «Юные инспекторы дорожного движения»: «Как перейти улицу, если нет светофора?» | Спортплощадка | 24.05.2018 | Воспитатели ГПД |

## 6. Ожидаемые результаты реализации проекта

1. Формирование навыков безопасного поведения младших школьников на дорогах, с целью предупреждения детского дорожно-транспортного травматизма с учетом требований ФГОС.
2. Обучение младших школьников правилам безопасного поведения на дорогах.
3. Воспитание чувства ответственности за личную безопасность.
4. Развитие самостоятельности, активности, мотивацию к безопасному поведению.

### 6.1. Прогнозируемые социальные эффекты

6.2.

| 1 | 2 |
|---|---|
| **Стейкхолдеры** | **Социальные эффекты** |
| Учредитель | Участие в конкурсе «Безопасное колесо» |
| Обучающиеся | Коммуникативное, творческое развитие; углубление знаний по ПДД |
| Родители | Безопасное поведение детей на дорогах |
| Педагогический коллектив | Формирование навыков безопасного поведения младших школьников |

| | |
|---|---|
| Партнеры | Меньше травматизма школьников |

## 7.Риски реализации проекта и пути их преодоления

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| **Риски** | Условия возникновения | Пути преодоления |
| **Финансовые** | Проведение ряд мероприятий по ПДД (нужны канцтовары, буклеты, наглядные пособия и т.п.) | Обратились к спонсорам |
| **Кадровые** | школа | Обратились к администрации школы |

## 8.Основные критерии и показатели эффективности реализации проекта

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| **Критерий эффективности** | Условие (%) | Измеритель |
| **Культура поведения на дорогах и в транспорте** | 75 % | Анкеты, тесты |

## 9. Заключение

В ходе реализации проекта «Формирование безопасного поведения младших школьников на дорогах с учетом требований ФГОС» предполагаемые результаты были достигнуты: мы обогатили опыт детей, создали необходимые условия для работы по предупреждению детского травматизма на дорогах, повысили компетентности родителей в обеспечении безопасной жизнедеятельности детей путем использования разных методов и приемов. Собрали богатый материал по безопасности дорожного движения и обобщили как опыт работы по данному проекту.

В период работы над проектом пополнился словарный запас учащихся. На протяжении всего проекта у детей сформировалось стремление к познанию объектов окружающего мира, научились делать простые выводы, устанавливать причинно – следственные связи; дети стали уверенно отличать и называть правила дорожного движения на улице.

Просвещение родителей дало большой плюс в социальном воспитании детей группы. Главное для воспитателей и родителей в приобщении школьников к правилам дорожного движения – донести до детей смысл, необходимость знаний и навыков по данной проблеме. И всегда необходимо помнить, что ребенок учится законам дорог, беря пример с членов семьи и других взрослых. Ведь мало, просто прочитать, рассказать, научить ребенка, нужно показать как правильно вести себя на улице. Иначе всякое целенаправленное обучение теряет смысл.

И в заключении хочется сказать, что каждому педагогу, которому доверено воспитание детей, необходимо овладеть современными научно – педагогическими знаниями, основанными на практическом опыте и рекомендациях работников ГИБДД.

Только тогда число дорожно – транспортных происшествий с участием детей значительно уменьшится. Понимая проблему безопасности дорожного движения и осуществляя планомерную, и целенаправленную работу по формированию у школьников основ безопасного поведения на дорогах и улицах города, мы можем предположить, что полученные знания пригодятся учащимся и родителям школьников в дальнейшем и сохранят не только здоровье, но и жизнь

В дальнейшем планируется продолжить работу в этом направлении: разрабатывать сценарии для проведения занятий, развлечений, праздников, досугов, памяток по ПДД. Так же планируется продолжить дальнейшее сотрудничество с инспекторами по пропаганде ГИБДД.

Разработать программу по профилактике детского дорожно-транспортного травматизма, составить сборник материалов (пособие, который бы, включил в себя теоретический и, большей частью, практический материал) по формированию, развитию и повышению уровня компетентности безопасного поведения не только у детей младшего школьного возраста, но и у воспитывающих их взрослых (педагогов и родителей).

## 10. Использованные ресурсы:


1. Авдеева, Н.Н., Князева О.Л., Стеркина Р.Б. Безопасность. Учебно-методическое пособие по основам безопасности жизнедеятельности детей младшего школьного возраста. − М.: Детство-Пресс, 2007. − 144с.
2. Байбородова, Л.В. Методика обучения основам безопасности жизнедеятельности: метод.пособие./ Л.В. Байбородова, Ю.В. Индюков. – М.: Гуманит. изд. центр ВЛАДОС, 2003. – 272 с.
3. Безопасность жизнедеятельности: учебное пособие/ сост. Л.А. Акимова, Г.А. Матчин, В.В. Конев, в.Ф. Трусов. – Оренбург: Изд-во ОГПУ, 2008. – 204с.
4. Болотов, В.А. Прагматичность и практичность должны лежать в основе курса ОБЖ / В.А. Болотов // ОБЖ. Основы безопасности жизнедеятельности. – 2003. − №2. − С.3−5.
5. Газета «ПДД», №6 , 2013 г.
6. Егорова, Э.Я. Педагогические условия формирования у школьников позитивного отношения к здоровью и безопасному поведению. Дис. на соискание уч. степени к.п.н. − Йошкар-Ола., 2004. − 199 с.
7. Закон «О безопасности дорожного движения», в 2005 г.- федеральная целевая программа «Повышение безопасности дорожного движения в 2006-2012 годах».
8. Иовенко. И.В. Теория и практика формирования у учащихся общеобразовательной школы культуры безопасности жизнедеятельности в чрезвычайных ситуациях. Дис. на соискание уч.степени д.п.н.−М., 2003.−408 с.
9. Козловская, И.А. Организация занятий по обучению школьников безопасному поведению на улице / Справочник старшего воспитателя школьного учреждения. − №6 .– 2009. – С. 29−34.
10. Михайлов, Л.А. Групповая форма организации работы на уроках ОБЖ / Л.А. Михайлов // ОБЖ. Основы безопасности жизни. – 2005. − №8. – С.6−12.
11. Мошкин, В. Воспитание культуры личной безопасности // Основы безопасности жизнедеятельности . − 2000. − № 8. − С. 13−16.
12. Науменко, ЮЛ. Пути и механизмы эффективного формирования навыков безопасного поведения школьников. /ЮЛ. Науменко //Актуальные проблемы профессионального образования в современных условиях. − М.: Академия педагогических и социальных наук, 2009. − 169 с.


## 11. Глоссарий

1. **УГИБДД МВД** - Управления Государственной инспекции безопасности дорожного движения
2. **ПДД** - правила дорожного движения

# ВАТАН ТАРИХЫНДА – ГАИЛӘМ ЯЗМЫШЫ

*Минниханова Гөлия Фәнис кызы, 10 сыйныф*
*Фәнни җитәкче - Галеева Нәсимә Хөсәен кызы,*
*Мамадыш муниципаль районыТүбән Ушмы урта гомуми белем мәктәбе*

**Тикшерү объекты**: туганнар, өлкән буын вәкилләре.

**Предметы:** документлар, фотографияләр, язып алынган истәлекләр.

**Тикшеренү максаты**:

Ватан тарихы белән гаиләләр язмышының үзара бәйләнешен ачыклау.

Кешеләрнең башларыннан үткәннәре, кичерешләре аша хәзерге буында горурлык хисе тәрбияләү.

**Бурычлар:**

1.Ватан тарихы белән кызыксыну уяту, халык хәтерен барлау;

2. Патриотлык һәм гражданлык хисе тәрбияләү;

3.Гаиләнең әхлакый кыйммәтләрен ачыклау,буыннар арасындагы бәйләнешне күрсәтү.

**Фәнни эштә кулланылган методлар:**

туганнар, өлкән буын вәкилләре белән очрашулар;
күзәтү;
документлар, чыганакларны өйрәнү;
сорашу;
тупланган мәгълүматьне эшкәртү;
фәнни эшемдә куллану;

**Чыганаклар:** гаилә архивыннан алган фотографияләр ,язып алынган истәлекләр, музейдан һәм архивтан алынган материаллар.

**Теманың актуальлеге:** буыннар арасындагы бәйләнешне хәзерге буын яшьләре начар белә.Өлкән буында бу бәйләнеш ныграк саклана. Нәсел шәҗәрәсен белү - ул Ватан тарихын, нәсел тарихын саклау, киләчәк буыннарга тапшыру дигәнне аңлата.

## Кереш өлеш

Тарихи вакыйгалар. Бу сүзне ишеткәч , күз алдында бер-бер артлы вакыйгалар кайтавазы чагыла. Хәзерге буын балалар бу вакыйгалар турында укыган китаплардан, каралган кинолардан, төрле чыганаклардан, тере шаһитләребез-әби-бабаларыбызның сөйләүләреннән белә. 20 гасыр тарихы: беренче бөтендөнья сугышы, күмәкләштерү еллары ,репрессия һәм террор еллары, Бөек Ватан сугышы, сугыш чоры балалары, Әфган сугышы, Чечен сугышы. Җаннарны тетрәндерүче вакыйгалар.Бу тарихи вакыйгалар минем гаиләм, нәселем тарихында чагылыш таба.Һәр халыкның үз язмышы,үз тарихы бар. Минем фәнни эшемдә халкым язмышында гаиләм тарихының чагылышы турында язасым, аңлатасым килде.Хезмәтемне язганда мин шуны аңладым: барысы да тарихта кала. Без үзебезнең тарихыбызны, үткәнебезне онытырга хакыбыз юк! Буыннар арасындагы бәйләнеш сакланырга тиеш! Эшемнең актуальлеге дә менә нәрсәдә.Мин «Хәтер» китабыннан , газета-журналлардан, музей материалларыннан файдаландым, туганнарым зур ярдәм күрсәттеләр,без зур эзләнү эше алып бардык. Гаиләм шәҗәрәсен өйрәнеп, Ватан тарихының гаиләм тарихында чагылышын ачыкладым.

## Төп өлеш

Нәсел шәҗәрәсен өйрәнергә миңа Сәләхетдинова Нурлыбикә Габдулла кызы ярдәм итте. Анда истәлекле тарихи чыганак: Бөек Ватан сугышында һәлак булган абыйсы – Абдуллин Хөсәен Габдулла улының латин телендә язылган блокноты саклана. Анда Түбән Ушмы авылының тарихы һәм нәсел шәҗәрәбез язып калдырылган. «Безнең нәселдә төрле һөнәр ияләре булган» - дип башлады сүзен Нурлыбикә әбием. Алар төрле тарихи чорларда яшәгәннәр, аларның төрле һәм катлаулы язмышлары булган. Ләкин алар гадел, хезмәтне яратучан кешеләр. Нинди генә чорда яшәсәләр дә, үз тормышларын лаеклы алып барганнар.

Безнең каршыбызда гаилә альбомыннан алынган фотолар, тарихи истәлекләр.Минем алдымда гаилә тарихы картинасы ачыла.

Бабам- Сәләхетдинов Хөсәен 1928нче елда Түбән Ушмы авылында туа. Мәктәпне тәмамлаганнан соң, Мамадыш педагогия училищесында укыган. Аннан соң читтән торып укытучылар институтын бетергән. Казан дәүләт педагогия институтының татар теле бүлеген уңышлы тәмамлый. Укуын тәмамлаганнан соң, Аксубай районының Иске Ибрай мәктәбенә укытырга җибәрелә, аннан армиягә алына.Владивостокта хезмәт итә. Солдат хезмәттеннән соң туган якларына кайта. Мамадыш районының Көек-Ерыкса мәктәбендә 10 ел мәктәп директоры булып эшли. Аннан соң Мамадыш район комитетына эшкә алына. 1965-1985 нче елларда авылыбызда партия оешмасы секретаре булып эшли. Яхшы хезмәте өчен Ленин ордены, медальләр, күп санлы мактау грамоталары белән бүләкләнә. Әбием Нурлыбикә һәм Хөсәен бабам дүрт бала тәрбияләп үстерәләр. Дүртесе дә югары белемле: уллары Илсур – инженер, Раиф – физика –математика укытучысы, кызлары – Нәсимә

һәм Розалия - эти - әниләре һөнәрен дәвам итә: тарих һәм татар теленнән белем бирәләр.

Ә Хөсәен бабамның әтисе Сәләхетдин бабай - урта хәлле крестьян. Ике аты, ике сыеры, амбары булган. Бөек Ватан сугышында катнашкан. Сталинград сугышында авыр яралана һәм хәбәрсез югала.

Сәләхетдин бабамның әтисе Җиһанша бабай шулай ук урта хәлле крестьян. Малайлары күп булу сәбәпле, җире күп булган. Игенчелек белән шөгыльләнгән. Икмәкне атларга төяп, Казанга алып барып сата торган булган. Кулак дип таланган, йортыннан куылган. Бабайны төрмәгә алып киткәннәр, төрмәдә үлгән. Җиһанша бабай гаилә учагын матур итеп саклый белгән, балаларын хезмәт сөючән итеп үстергән. Балалары күп булган: Сәләхетдин, Габделхак, Әгъләметдин, Фәхригаләм, Гомәр.

Һәр буын бабаларыбызның язмышында тарихи чор сүрәтләнгән. Дүртенче буын бабам- Кәбир исемле булган. Уртача тормышта яшәгән, игенчелек , терлекчелек белән шөгыльләнгән. Балалары: Җиһанша, Мәхмүт, Мәсгут исемле булган. Бишенче буын бабам – Биктимер. Игенчелек, терлекчелек төп кәсепләре булган. Авыл халкына дини белем биргән, яктылыкка өндәгән.Гәрәп, татар телләрендә укый, яза белгән. Балалары: Кәбир, Латыйфа, Таһирәбану.

Алтынчы буын бабам – Муса. Биктимер, Җәмилә, Муллахәсән, Исмәгыйль исемле балалар үстергәннәр.

Җиденче буын бабам – Хафиз исемле. Балалары: Зариф, Сәет исемле булган.

**1914 нче елгы** беренче бөтендөнья сугышы Нурлыбикә әбием ягыннан нәсел шәҗәрәсендә чагылыш таба. Әбиемнең әтисе Габдулла бабай 1914нче елгы сугышта катнашкан. Әсирлеккә төшкән, бер ел алпавытка эшләгән. Хуҗа үзенең кызына өйләнергә тәкъдим иткән. Ләкин ул туган ягына кайткан. Балалары күп булган: Маһиҗамал, Хөсәен, Хайрулла, Хабибулла, Таһирәбану, Мәрямбикә, Нурлыбикә, Вәлиулла. Вәлиулла абый сугышта үлгән.

Икенче буын - Әхмәтҗан бабам. Таза тормышлы кеше булган. Ике яклы йорты, сыерлары, атлары булган. Урак урганнар, терлек асраганнар. Балалары: Вәлиулла, Габдулла, Гиззатуллла, Мөхәммәтҗан, Бибигайшә.

Өченче буын – Габделкәрим бабам. Игенчелек, терлекчелек төп кәсепләре булган. Балалары: Әхмәтҗан, Исмагыйл, Җәмил.

Дүртенче һәм бишенче буын бабаларыбыз: Биктимер һәм Мусада нәсел җепләребез тоташа.

Алтынчы буын – Кадыйр бабам. Исрафыйл, Гиззатулла, Таһирәбану, Мәрямбикә исемле балалар үстергәннәр.

Җиденче буын – Ибраһим бабам. Бибиҗамал, Искәндәр, Галиулла исемле балалар үстергәннәр.

## Күмәкләштерү еллары

Габдулла бабай, Җиһанша бабай - урта хәлле таза тормышта яшәгәннәр. Беренчеләрдән булып колхозга кергәннәр. 1929-30 нчы елларда авылымда колхозлар төзелгән. Аңа “Кзыл флаг” исеме бирелгән. Ул өч авылны берләштергән: Түбән Ушмы, Хафизовка, Үрнәк. Ике бабам да таланып, байлыклары тартып алынган. 2004 нче елда гына акланганнар.

Мин менә шулай җиде буыныбызны белү бәхетенә ирештем. Бу мәгълүматьләрне Габдулла бабамның улы Хөсәен абый язып калдырган. Олы яшьтәге туганнарымнан сорашып, шактый мәгълүматъ тупладым. Җиденче буынга кадәр әби-бабаларымның тормыш итүләре, кәсеп – шөгыльләре турында белдем. Нәселебез горурланырлык, затлы нәсел дигән нәтиҗәгә килдем.

## Репрессия еллары

Сәяси репрессия һәм террор еллары да минем нәселемдә чыгыш таба. Репрессия елларында газап чиккән, авылымның күренекле кешесе, туганыбыз – Габделхай Хадиев турында сөйләп китәргә телим. Габделхай Хадиев 1892 нче елда Мамадыш районы Вахит авылында туа. Бөтен гомерен ул игелекле һөнәр иясе – укытучылык эшенә багышлый. 1930 нчы елда Түбән Ушмы авылына директор итеп күчерелә. 1936-1939 нчы елларда Урта Кирмәндә эшли. 1938 нче елда Дүсмәт мәктәбендә укытучы, шул ук елның сентябрь аенда кулга алына. Гаиләдә хатыны – Мәдинә һәм биш бала кала: Нәсибә, Мансур, Нәзиха, Махсуд, Каюм.

«Халык дошманы» исеме тагылган гаиләгә яшәве җиңел булмый. Нәзихане ире ташлап китә. «Халык дошманы кызы белән яшәргә теләмим»- дигән сүзләре белән йөрәкне яралый. Нәзыйха апасы Нәсибә гаиләсендә яши. Габделхай Хадеевның хатыны Мәдинә ханым да хәерчелектә яши. Уллары Каюм бу куркыныч еллар турында сөйләгәндә «ике ел буе киенеп йокладым, мине дә килеп алырлар» - дип курыктым дип яза.

Түбән Ушмы авылында районда беренче буларак ике катлы мәктәп салына.

Мәктәпнең елга буенда салынуы, тиздән ишелеп төшәчәге турында жалоба языла. Әтиләренең муллалык эше белән шөгыльләнүе дә исәпкә алына. Салынган мәктәп 1987 нче елга кадәр хезмәт итә.1935 нче елның 21 нче ноябрендә Габделхай абый партия сафларыннан чыгарыла. «Сәяси грамотасызлык, пассивлык, таныш булмаган элементлар белән элемтәдә торганы өчен гаепләнә». Мондый элементлар булып әтисе һәм абыйсы санала.1936 нчы елның 16 нчы апрелендә икенче карар чыгарыла:1938 елның 28 сентябрендә кулга алына. Аның ахыргы сүзләре булып: « Мин гаепле түгел, бу аңлашылмаучанлык, мине тиздән азат итәрләр» - дип ышанам дигән сүзләр яңгырый. Аны Алабугага, соңыннан Казанга җибәрәләр. 1940 елның августында «Совет хакимиятенә каршы пропаганда алып барган өчен, 8 елга ирегеннән мәхрүм ителә.

1942 елда гаиләгә бердәнбер хат килә. «Миңа ярдәм кирәк, булдыра алсагыз булышыгыз, мин гаепле түгел, исән кайтсам, барысын да сөйләрмен» - дип яза хатында. Ләкин кайтырга насыйп булмый. Архангельск шәһәрендә каты авырудан үлә.

Бу мәгълүматьне мин Габделхай Хадеевның улы Махсуд Хадеевдан язып алдым .Ул сугыш ветераны, тыныч тормышта озак еллар укытучы булып эшли. Кызганычка каршы исән түгел, 90 яшендә вафат була.

## Бөек Ватан сугышы чоры

Сугыш темасы искерми. Кешелек дөньясы Җир шарына үлем чире белән янаган фашизмны, үз оясына куып кертеп, тар-мар итте. Илебез халыклары, якыннарыбыз, туганнарыбыз тир һәм кан түгеп, бөек Җиңүне яулады. Газиз гомерләрен биреп, бүгенге матур тормышны тәэмин итте. Моның турында онытырга ярамый. Җиңүгә өлеш кертүчеләр арасында гап-гади татар егете – Абдуллин Хөсәен Габдулла улы да бар. Сугышның фаҗигале көннәре елдан-ел ераклаша бара. Бу сүз үзенә күпме фаҗига, җан ярасы сыйдырган. Җимерелгән язмышлар, өзелгән гомерләр...

Кулымда сугыш чоры фотолары һәм озак ятудан саргайган сугыш чоры хатлары. “Хәтер китабы”нда Абдуллин Хөсәен турында саран гына өч юл язылган. Ләкин бу юлларда

тулы бер кеше гомере, үз Ватаны өчен көрәшеп һәлак булган солдатның фаҗигале язмышы чагыла.

Кеше сугыш өчен тумый, яшәми дә. Хөсәен дә балачагыннан ук туган авылы Түбән Ушмының табигатенә гашыйк булып үсә. Тыңлаучан, эш сөючән малай Тегермән буасында балып тотарга яраткан. Әтисе Габдулла абый гармунда уйнаганда, аңа кушылып җырлый торан булган. Әтисеннән күп төрле һөнәрләргә өйрәнеп үсә ул.

1932 нче елда башлангыч, 1937 нче елда 7 еллык мәктәпне тәмамлый. 1937-1939 нчы елларда Мамадыш педагогия училищесында укый. Аннан соң Кече Кирмән 7 еллык мәктәбендә тарих укытучысы булып эшли башлый. Шул ук елны Казан педагогия институтының тарих бүлекчәсенә читтән торып укырга керә.

“ Абый авылыбызның тарихын тырышып өйрәнде. Җиде буынга кадәр шәҗәрәбезне язып алды. Балаларны бик ярата иде”, - дип сөйли сеңлесе Нурлыбикә апа.

Ләкин аңа укытучы булып озак эшләргә насыйп булмый. 1939 нчы елның октябрь башында хәрби хезмәткә чакырыла, Ерак Көнчыгышта хезмәт итә башлый. Хатларын гел язып тора. Бер хатында туган ягын сагынуы турында:

“Даланың салкын җилләре
Үзәккә кадәр үтә.
Их, дусларым, туган якка
Бу дөньяда ни җитә”, - дип яза.

1940 нчы елның җәендә Эстониягә күчерелә. Әтисенең үлеме турында хәбәрне Тарту шәһәрендә ала.

Бөек Ватан сугышы башлангач, 348 нче укчы дивизиянең 1172 нче укчы полкы автоматчылар бүлеге командиры сержант Хөсәен Абдуллин Ватаныбызның күп җирләрен азат итүдә катнаша, берничә мәртәбә яралана. Медальләр белән бүләкләнә. Шигъри җанлы егет әнисен хатларыннан өзми. Сеңлеләренең авыр шартларда да укуларына сөенә, әнисенә тырышлыгы өчен зур рәхмәт белдерә.

1943 нче елның 20 нче маенда язылган хатта:”Авыл Советының сезгә мөнәсәбәте ничек? Сезне салым белән газаплыйлардыр инде. Хуҗалык эшләре ничек бара ?”, - дип яза.

Әниләре Маһирә апа алны-ялны белмичә эшли. Ачлыкка-ялангычлыкка бирешмичә ике кызын да укыта. Кызлары Нурлыбикә белән Таһирәбану әниләренә зур ярдәм күрсәтәләр, белем алалар. Алар икесе дә югары белем ала. Озак еллар төрле мәктәпләрдә укытып, лаеклы ялга чыгалар. 1944 нчы елның башында Хөсәен абыйларыннан хатлар килү туктый. Ана белән балалар ут йотып йөргәндә, салкын февраль иртәсендә өйгә шатлыклы хәбәр килеп ирешә. Хафизовка авылыннан килгән туганнары Хөсниямал апа Хөсәеннең туганнарында җылынып калуын, тиздән өйгә кайтып керәчәген әйтә.

“Башта әни тораташ булып булып катып калды. Бу хәбәргә ышанырга да, ышанмаска да белмәде. Аннан абый турында сораша башлады. Мин абый каршына чыгып йөгердем, әни табын әзерләп калды”, - дип искә ала Нурлыбикә әби.

Озакламый Хөсәен, сеңлесен ияртеп, үзе дә кайтып керә...

Кукмарага икмәккә кайткан эшелонга эләккән икән. Командирыннан бер тәүлеккә өенә кайтып килергә рөхсәт алган. 80 чакрымга якын араны җәяү кайткан. Өйдәгеләр аның икенче көнне үк яңадан фронтка китәсен белгәч, күңелсезләнеп калалар.

Санаулы минутлар бик тиз үтеп китә; 4 ел сугышта һәм ике ел армия хезмәтендә булган егет яңадан юлга әзерләнә. Бу вакытта алар соңгы кабат күрешеп калуларын башларына да китермиләр. Тышта 30 градустан артык суык. Чылбырыннан ычкынган февраль җиле арсландай үкерә. Озак йөреп хәлсезләнгән юлчыдай тәрәзә шакый, морҗа эченә, бүрәнә ярыкларына кысылып үкси, елый. Әнисенең хәер-фатыйхасын алган фронтовикны авыл халкы, туганнар озата. Кукмарага ат белән Нотфулла абыйсы озата чыга. Ләкин хәлсез ат ерак китә алмый. Алкин урманыннан соң егеткә җәяү китәргә туры килә. Бераз баргач, озата чыккан туганы янына кире әйләнеп килә. Күз яшьләрен күрсәтмәскә тырышып, үзенең солдат бияләйләрен әнисенә истәлеккә тапшырырга куша. Туганы үз бияләйәрен аның кулына тоттыра. Азык – төлек салынган солдат капчыгын тотып,

фронтовик егет Кукмара ягына юнәлә. Юлдан да, сугыш эченнән дә шактый хатлар язып сала. “Фашистларны куа барабыз, тиздән җиңү белән кайтырбыз. Сез ничек тә булса түзегез инде”, - дип яза хатларыда. Соңгы хаты Белорусиядән килә. 1944 нче елның март аенда Маһирә апа Әхмәтҗанова өенә кара кәгазь килеп

төшә. Хатта Хөсәен Абдуллинның 4 нче март көнне батырларча һәлак булуы һәм Гомель өлкәсе Рогочев районы Старое Село авылы зиратында күмелүе хәбәр ителә. Аңа бу вакытта нибары 23 яшь була.

“Әни абыйның үлемен бик авыр кичерде, ул язган хатларны, фотоларын, солдат бияләен кадерләп саклады. Күпме күз яшьләрен түкте, әни 1946 нчы елда үлде”, - дип искә ала Нурлыбикә әбием.

Сугышта һәлак булганнарның исем- фамилияләре һәйкәлләргә уелган, Хәтер китабына кертелгән. Шул рәвешле аларга ихтирамыбызны белдерәбез. Мәңгелек дан аларга! Җиңүне тизләтүдә үзеннән өлеш керткән Хөсәен Абдуллинның да исеме онытылмасын, якты истәлеге саклансын!

Хөсәен бабамның әтисе Сәләхетдин бабам да сугыш авырлыкларын күрә. Сталинград сугышында хәбәрсез югала. Сугыш чоры авырлыклары тыл хезмәтчәнләренең тырыш эшчәнлекләре белән артка чигерелә.

**Сугыш чоры балалары. Тыл хезмәтчәнләре**

Сәләхетдинова Нурлыбикә Габдулла кызы – сугыш чоры баласы, тыл һәм хезмәт ветераны, ветеран укытучы. Кырык еллык педагогик белемен балалар укытуга һәм тәрбияләүгә багышлый. Тыл хезмәтчәнләре үз-үзләрен аямаганнар, авызларыннан соңгы телем икмәкләрен өзеп, бар булган ризыкларын фронтка озатканнар. Балаларым ачтан үлә күрмәсеннәр, кеше булсыннар, - дип ачы хәсрәт йотып яшәгән апалар, әниләр, әбиләр...

Ил язмышы, ил кайгысы белән яшәп, гаилә бәхете күрә алмый картайганнар, кычыткан, какы, алабута ашап, икмәккә тилмереп үскән, илнең төп таянычына әверелгән балалар – яшүсмерләр.

Әбием 1928 нче елның 23 нче июнендә Түбән Ушмы авылында крестьян гаиләсендә дөньяга килгән. Әтисе – Габдулла бабай урта хәлле крестьян булган. 1937 нче елда әбием Түбән Ушмы җидееллык мәктәбенә укырга керә. 1941 нче елда сугыш башланганда, дүртенче класс укучысы була. 1940 нчы елда тиф авыруы чыгып, авылдагы ирләрнең күбесе бу чирдән кырыла. “1940 нчы елның июль аенда әтием тиф белән авырый башлады. Унике көн буенча каты авыру белән көрәште. Сау-сәламәт, 53 яшьтә генә иде”,- дип искә ала әбием. Гаиләгә килгән авырлыклар берсе артыннан берсе дәвам итә.

1941 нче елның 22 нче июне, канкойгыч сугыш башлана. Авылдагы бөтен эш хатын-кыз, балалар җилкәсенә төшә. “Әниләр белән бергә урак урырга, утауга йөрибез. Бәрәңге алынып беткәч, басуга барып, черек бәрәңге казып алып кайтабыз. Алабута оны белән кушып ипи пешерәбез. 25 километр ераклыкта урнашкан болынга барып, юа җыеп, алып кайтабыз. Ачка тилмергән чаклар күп булды”, - дип искә ала әбием.

Шундый авыр шартларда 1944 нче елда җидееллык мәктәпне тәмамлый Нурлыбикә әбием. “Бу елларда мәҗбүри уку булмый, укучылар укуны ташлап эшкә йөриләр. Аякта чабата, ямалып беткән оек, өстә – әтидән калган

олы телогрейка. Чабатаны үзебез үрә идек. Өйне җылытыр өчен икешәр юл утынга барабыз. Салам алып кайтып та өйне җылытырга тырышабыз”.

Әти-әнисез, дөм ятим калган балалар язмышына тарих сәхифәләре ничек язылган соң? Әтисез калганда әбиемә-12, әнисе үлгәндә-18 яшь булган.Өйдә ике ялгыз кыз бала.1945 нче елда әбием Мамадыш педагогия училищесына укырга кергән. Анда уку еллары да бик авыр була. “Кеше тормый торган иске йортларны табып, җимерелгән коймаларны сүтеп, утын итеп ягабыз. Һәркем бәләкәй чуен белән бәрәңге пешерә. Ипи юк, кабыклы бәрәңге ашыйбыз”. 1947 елда училищены тәмамлап, Түбән Ушмы мәктәбендә укыта башлый. “Класста ике-өч ел күчмичә калган балалар. Өсләренә киярга кием юк. Бөтен җирдә хәерчелек хөкем сөрә”,- дип искә ала хатирәләрне әбием. Шул ук елда Алабугага читтән торып укырга керә. Ике араны җәяү йөрү,бернинди транспорт та юк. Алабугада институт

тәмамлаганнан соң, укуны Казан педагогия институтында дәвам итә. Үзенең тырышлыгы, тормыш авырлыкларына бирешмәүләре нәтиҗәсендә әбием тормышта иң игелекле һөнәрне сайлый, укытучы булып җитешә. Әбием укытучы һөнәрен игенче һөнәре белән чагыштыра.Укытучы бала күңеленә белем орлыгы чәчә,тәрбия бирә. Бала үсеп җиткәч, алган тәрбиясен, белемен кулланып, халкына хезмәт итә. Укытучыдан башка беркем дә һөнәргә өйрәнә алмый. Укытучы-барлык һөнәрләргә юл ачучы. Укытучы- иң мактаулы һәм намуслы хезмәт", -ди әбием.

1954 нче елда үзенә тиң ярны таба, күрше егете - бабам Сәләхетдинов Хөсәен белән гаилә кора. 1955-1965 нче елларда-Көек-Ерыкса мәктәбендә рус теленнән белем бирә, укыту эшләре буенча директор урынбасары булып эшли. 1965 нче елда әби-бабам туган авылына әйләнеп кайта.Һөнәренә тугры калып озак еллар буенча мәктәптә укытучы булып эшли. Абыйсының амәнәтен үти. Гаиләдә дүрт бала тәрбияләп үстерәләр. Гаиләдә укытучылык стажы 150 елны тәшкил итә. Чын мәгънәдә -мәгърифәтле гаилә. Әбиемнең кырык еллык укытучылык стажы бар. Ничә буын укучыларга белем һәм тәрбия бирелгән. Ә иң зур бүләге - аның укыткан укучылары, эти-әниләренең рәхмәт сүзләре. Хәзерге көндә әбием- лаеклы ялда. Ныклы ихтыяр көчле, авырлыклар алдында сынатмаучы кадерле әбием, хәзерге көненә шөкер итеп яши. "Хәзерге буын,балалар, оныклар-без күргән авырлыкларны күрмәсен,бәхетле яшәсеннәр",-дигән теләктә кала. Ул- безнең гаиләнең иң хөрмәтле кешесе. Кирәкле вакытта үзенең яхшы киңәшләрен бирә, ярдәм кулы сузарга һәрвакыт әзер . Балалар һәм оныклар өчен үрнәк, гаиләбезнең –горурлыгы ул.

**Әфган сугышы**

Еллар узган саен, канлы вакыйгалар ерагая, истәлекләр тоныклана барса да, әле һаман да "Әфганстан» сүзе газиз уллары таш-кыялар арасында башын салган бик күп аналарның җаннарын тетрәндерә. Беркем өчен дә кирәк булмаган, очсыз-кырыйсыз һәм җиңүчеләрсез бу сугыш әниләрне бик иртә картайтты. Без тарихтагы кайгылы көннәрне онытырга тиеш түгелбез.

1979 нчы елның 25 декабреннән алып- 1989 нчы елның 15 февраленә кадәр Әфганстан җирендә совет хәрбиләре интернациональ бурычларын үтәүдә катнашкан. Бу сугышта Татарстан буенча 432 кеше катнашкан, 256-сы һәлак булган. Безнең авылдан киткән солдатларның Илфат Хабибуллиннан башкалары барысы да исән-сау әйләнеп кайткан. Менә алар:

1.Сафин Мансур
2.Мухаметзянов Рашит
3. Мухаметзянов Әлфәт
4. Муртазин Мубарәкҗан
5. Муртазин Илсур
5. Каюмов Зөфәр
6. Муллахметов Рамил
7. Гиззатуллин Илсур
8. Ганиев Наил
9.Хафизов Рамил

Ватан сакчысы булу дәрәҗәле, абруйлы булып саналган. Илфат 1984 нче елның 23 октябрендә Совет Армиясе сафларына алына. Ашхабад шәһәрендә 6 ай хәрби әзерлек үтә. Хәрби өйрәнүләр үткәннән соң, Хабибуллин Илфатны Әфганстан республикасына хәрби хезмәткә күчерәләр. Рядовой шофер Хабибуллин Илфат Кыям улы Пули-Хумри шәһәрендә интернационал бурычын үти.Үзенең грузовой машинасы белән сугыш кирәк-яраклары ташый. Шулай бер көнне колонна белән машинада снарядлар алып барганда, уйламаганда, дошманнар төрле яктан гранатометтан колоннага ата башлыйлар. Бу сугышта бик күп яшь егетләрнең гомерләре өзелә. Хабибуллин Илфат йөртеп бара торган машинага дошман снаряды тия. Снарядлар төялгән машина туктап кала.Ул Әфганстан җирендә бары 6 ай

хезмәт итә. Яшь комсомолец, Хафизовка авылы егете Хабибуллин Илфат Кыям улы 1985 нче елның 23 августында интернационал бурычын үтәгәндә батырларча һәлак була.

## III. Йомгаклау өлеше

Фәнни эшне тәмамлап, мин түбәндәге нәтиҗәләргә килдем:

**1.** Нәсел агачын – шәҗәрәне төзегәндә, мин горурлану хисләре кичердем. Кайсы чорда яшәгән нинди генә туганымның тормышы, яшәеше турында белешсәм дә, һәрберсенең эшчән, уңган, алтын куллы, булдыклы булуын белдем. Шуның өстенә нәселебезнең һәр буынына сабырлык, башкаларга ярдәм кулы сузу, белемгә омтылу кебек матур сыйфатлар да хас икән.

Һәрберсе тормышта үз урынын табып, бүтәннәргә үрнәк булып, дөньяның ямен, тәмен, ләззәтен белеп яшәгәннәр, яшиләр, яшәрләр дип ышанам.

**2.** Нәсел шәҗәрәмдә ике төрле һөнәр өстенлек итә: укытучылык һөнәре гаиләдә 150 елны, нәселдә 420 елны тәшкил итә. Яңа буын тарафыннан икенче һөнәргә нигез салына. Ул инженерлык профессиясе, 80 ел белән исәпләнә.

3.Гаилә тарихы, ил тарихы бер берсеннән башка була алмый. Халкым елъязмасында гаиләм тарихы- бер тамчы су кебек кенә. Минем фикеремчә, без үткәнебезне онытмаска тиеш, бу ядкәрьләр буыннан-буынга тапшырылсын.

4.Горурланырлык зур язмышыбыз, чал тарихыбыз бар. Рухи гамьсезлек – иң зур ямьсезлек.

5. Олы диңгез тамчылардан, ә тарих истәлекләрдән җыйнала.

6. Хезмәтемне тәмамлап, шуны әйтәсем килә: минем нәселем тарихи мәгълүматьләргә бай юл узган. Тамырларыбызны барлыйк, кадерен белик.

7.Тормышта чагылыш тапкан кардәшлек хисе нәсел ыру тарихы баесын, хәзерге буын лаеклы дәвамчы булып үссен.

*Кулланылган әдәбият*


1. Р.Р. Идиатуллин “Хәтер” Татартан Республикасы, Казан 1996 ел
2. Ә.Н. Хуҗиәхмәтов “Хәтер уты” 1 том, Татартан Республикасы “Хәтер нәшрияты” 2006 ел.
3. З.Р. Валиева “Хәтер китабы” тарих институты 2009 ел.
4. Р.Ш.Мустаев “Афганистан живет в моей душе” патриотическое издание Казань 2004 год.
5. А. А. Иванов “Книга памяти жертв войны в Афганистане” РТ Казань 1999 год
6. Гаилә архивыннан фотолар, документлар,музей материаллары.
7. Өлкән буыннан язып алынган истәлекләр


# МИН – ДАНЛЫКЛЫ НӘСЕЛ ДӘВАМЧЫСЫ


*Мифтахов Әсхәт Фоат улы, 6 сыйныф*
*Фәнни җитәкче - Мифтахова Руфия Билсур кызы, Балтач муниципаль районы Арбор төп гомуми белем бирү мәктәбе*


## Кереш

Бу хезмәткә алынуга этәргеч булып, Бөек Җиңүнең 72 еллыгына багышланган кичәдә үзем сөйләгән шигырь тора. Ул шигырьнең авторы- минем әнием - аны үзенең бабасына, ягъни минем дәү бабама багышлап язды. Кызганыч, мин бабайларымны бары тик фотосурәтләреннән генә күреп беләм. Әтием белән әнием дә - бабайлары вафат булгач туган балалар. Әнием ягыннан әбиемнең дә, бабаемның да әтиләре тырыш, акыллы, хөрмәткә лаек ир-егетләр булган. Икесе дә Бөек Ватан сугышында катнашкан.

Әмма сугыш яралары, тынгысыз елларның газаплары эзсез үтми: Мәгъсүм бабам - 42 яшендә, Зиннәтулла бабам 63 яшендә вафат булганнар. Әлеге шигырьне өйрәнгәннән соң миндә бабаларым тормышы, язмышы турында беләсе килү теләге уянды. Үземнең шәҗәрәм, җиде буыным турында уйландым. Мин ата-бабаларымның, әти-әниемнең кылган әйбәт эш-гамәлләрен дә онытмаска, күркәм гореф-гадәтләрен дәвам итәргә, нәсел шәҗәрәбезне җентекләп өйрәнергә тиешмен. Буыннар чылбырында ата-бабамнар нинди эз калдырганын, гомумән, авылым тарихында нинди истәлекле чорлар булганын минем, мәктәп укучысы һәм шәхес буларак, тирәнрәк беләсем килә. Безнең нәсел агачының тармаклары кайларга барып тоташа икән соң? Билгеле, нәсел агачы төзеп кенә чикләнмичә, ул нәселдән кемнәр чыккан, алар кайларда, нәрсә белән шөгыльләнгәннәрен дә өйрәнергә кирәк, шул рәвешле матур традицияләрне дәвам итә алабыз. Менә шунда инде нәселең белән горурлану хисе туа да. Безнең борынгы бабаларыбыз нәсел-нәсәпләрен, бабаларын белеп кенә калмаган, туганлык җепләрен дә саклаган, бер-берсенә ярдәм иткән, уртак эшләрне өмә белән башкарган. Нәселдәге күркәм күренешләр хупланган, буыннан-буынга күчә барган, ә берәрсе ярамаган эш эшләсә, «нәселдә булмаганны» дип, ул яманлыкны эшләүчене әрләгәннәр. Гомумән, нәсел традицияләре – гаилә ныклыгының нигезе булып тора, уңай гадәтләр нәселдән-нәселгә күчерелә бара.

Шуңа күрә “Туган ягымда нәсел шәҗәрәсе” дигән юнәлешне сайлавым да - **практик яктан** зур әһәмияткә ия булган **актуальлекне** раслаучы факт.

Фәнни эшемнең **тикшерү объекты** - әнием ягыннан Зәкиевлар гаиләсенең шәҗәрәсе, **тикшерү предметы** – әлеге нәсел кешеләренең авыл тарихында тоткан урыны.

Эшемнең **максаты**: Буыннар чылбырында ата-бабамнар нинди эз калдырганын, безнең нәсел агачының тармаклары кайларга барып тоташуын, бу нәселдән кемнәр чыккан, алар кайларда, нәрсә белән шөгыльләнгәннәрен өйрәнү.

Максатка ирешү өчен түбәндәге **бурычларны** хәл итәргә кирәк:

1. Зәкиевлар нәселенең Арбор авылында таралуы кем исеме белән бәйле, аларның монда күчеп килүләренең вакытын һәм сәбәбен ачыклау.

2. Нәселнең күренекле вәкилләрен барлау, аларның авыл тормышына, үсешенә керткән өлешләре.

Әлеге хезмәтемне мөмкин кадәр дөрес һәм төгәл итеп башкару өчен, мин мәктәбебездә эшләп килүче “Туган якны өйрәнү” музеендагы материалларга, авыл һәм мәктәп китапханәсендә тупланган язмаларга, авылдашларыбызның истәлек-хатирәләренә таяндым. Эзләнү эшләре барышында төп чыганак булып 2013 елда авылдашыбыз, шагыйрь Гарифҗан Мөхәммәтшин тарафыннан нәшер ителгән “Урбар” китабы торды. Эшемне тарих һәм тел-әдәбият укытучылары җитәкчелегендә, аларның фәнни киңәшләре ярдәмендә башкардым. Эшебездә тарихи чыганакларны анализлау, чагыштыру, әңгәмә **методлары** киң кулланылды, тарих төпкелленә яшерелгән бик күп фактлар, вакыйгалар ачыкланды. Тыл ветераннары белән очрашу, аларның истәлекләрен тыңлау хезмәтемнең мәгънәсен һәм кирәклеген аңларга ярдәм итте.

**Бүлек 1. Шәҗәрәләрне белүнең мөһимлеге**

Җиде буын, буыннар бәйләнеше, шәҗәрә... Бу сүзләр тирән мәгънәгә ия. Гади генә әйткәндә, **шәҗәрә ул** – нәсел-ыруның кемнән башланып, ничек тармакланып китүен күрсәткән кульязма истәлек. Анда ата-бабалар исемлеге, нәсел тарихына бәйле вакыйгалар теркәлгән. Фәнни нигездә билгеләмә биргәндә, **шәҗәрә** – генеалогик язма – туган-тумачалык, һәр шәхеснең тормышы һәм кылган хезмәтләре хакында мәгълүмат алып була торган тарихи чыганак ул.

Генеалогик чыганаклар үз чиратында 3 төркемгә бүленә:

1. Сөйләм телендәге чыганаклар (риваять – легендалар);
2. Матди, материаль чыганаклар (медальләр, акчалар, тәңкәләр, дини әйберләр, герблар);

3. Язма чыганаклар (рәсми чыганаклар: кануни актлар, төрле таныклыклар, хезмәт кенәгәсе); тарихи чыганаклар – елъязмалар, шәҗәрәләр, язма кенәгәләр; гаилә чыганаклары – истәлекләр, төрле язмалар, шәхси хатлар, васыятьнамәләр.

Нәсел-ыру тарихы белән кызыксыну дөньядагы күп халыкларда күзәтелгән. Шәҗәрәләр белән шөгыльләнү һәм аны белү төркиләрдә, гарәпләрдә, германнарда киң таралган. Шәҗәрәләр белү әле язу белән таныш булмаган гасырларда ук күп халыкларга мәгълүм була. Галимнәрнең язуларына караганда, Тын океан утрауларында яшәүче халыкларда хәтта 80 буынгача нәсел тарихларын белгән кешеләр бар икән. Иң элеккеге шәҗәрәләр күпмедер дәрәҗәдә энциклопедик характерда була: аларда тарихи мәгълүматлар белән беррәттән халыкның көнкүреше, гореф-гадәте, фольклор – авыз иҗаты да чагылган.

Бу яктан мин - бәхетле нәсел баласы. Безнең нәсел шәҗәрәләре инде төзелгән. Миңа бары аларны тирәнтен өйрәнәсе генә. *(Кушымта 4,5)*

**Бүлек 2. Зәкиевлар шәҗәрәсе**

Бу нәселнең ерак тамырлары - Куныр авылында. Нәселнең билгеле булган иң ерак вәкиле – Габдрахман (1700-...). Аның биш баласы булып, Габдулла исемлесе (1737-1791) җиде балага гомер бүләк итә. Габдулланың Ишмөхәммәд (1758-...) улының да җиде баласы була. Безнең буын чылбыры буенча барсак, Мөхәммәдшәриф (1807-...), аннан соң Мөхәммәдшакир (1827) атлы ерак бабаларыбыз булган. Киләчәктә фамилиядә исеме сакланачак Мөхәммәдзәки бабабыз Мөхәммәдшакирның өч кыз арасындагы бик кадерле һәм бердәнбер улы булган. Үзенең дә, Фәриха әби белән гаилә коргач, өч кызы һәм бер улы туган. Нәкъ менә әлеге ул - безгә билгеле булган җиденче буын вәкиле, Бөек Ватан сугышы ветераны, бабаем Мәгъсүм Зәкиев әлеге нәселнең бер тармагын Арбор авылы белән бәйли дә инде. Бу гаҗәп түгел – Арбор һәм Куныр авыллары бер үк чорда нигезләнгәннәр. Алар арасында якын күршелек мөгамәләләре борынгыдан ук килә. Кыз алышу, кодалашу, сәүдә-зшмәкәрлек бәйләнешләренең тамырлары тирәндә. Хәер, бу очракта кыз алышу-кодалашуның катнашы юк. Мәгъсүм бабаемның җәмәгате – изге җанлы карт әбием Миңнур да Куныр кызы. Бабам 1943 елның августында Арбор авылы Советының рәисе итеп билгеләнә. Гаиләсен алып, шушында төпләнеп кала. Монда аларның тагын ике балалары туып, җәмгысе биш бала булалар. Минем Билсур бабаем, Кунырда туып, Арборга килгәндә ике яшьлек малай булса да, гомере буе Арборны яратып, аны туган авылы санап яшәгән, авылымның чын патриоты. Билсур бабамның биш баласы да әтиләре сызган ак юлдан атларга тырыша, кешеләргә игелек эшләргә, авылыбыз үсешенә өлеш кертергә омтыла. Безне – ун оныкны да шулай тәрбияли. Еш кына безгә бабайларыбыз турында, аларның тормышлары, язмышы хакында сөйлиләр. Кайнар йөрәкле, олы җанлы, җылы куллы кадерле кешеләребез турында без белеп үсәбез, аларны онытмыйбыз һәм үзебез дә кешеләр күңеленә яхшы эшләр белән кереп калырга тырышачакбыз. Мин – Зәкиевлар нәселенең унынчы буыны булуым белән горурланам.

**Бүлек 2. Зәкиев Мәгъсүм Зәки улы**

1916 елның 19 февралендә Куныр авылында туган. *(Кушымта 6,7)*

Белеме документларда “тәмамланмаган урта” дип теркәлгән. Хезмәт юлын әтисенең крестьян хуҗалыгында башлый. 1931 елдан – Куныр почта бүлекчәсендә почта агенты. 1933 елдан Куныр авылында оешкан “Правда” колхозының бригадиры итеп билгеләнә. Шушыннан 18 яшендә - 1934 елда Куныр авыл Советының секретаре итеп сайлана. 1935 елда шофер таныклыгы ала һәм, Киров өлкәсенең Шурма районы Пивовары авылында оешкан “8 март” колхозына машина алып кайтып, шофер булып эшли башлый.

1937 елда М.Зәкиев Кызыл Армия сафларына алына. Хәрби хезмәтне Киев шәһәрендә уза, шушында партия сафларына кабул ителә. 1940 елда, өлкән сержат дәрәҗәсендә хезмәтен тәмамлап, туган авылы Кунырга кайта, “Правда” колхозында шофер булып эшли.

1941 елның июлендә Ватан сугышына чакырыла. Смоленск юнәлешендә 18 нче укчы дивизия составында авыр сугыш операцияләрендә катнаша. Аңа Кызыл Армия бөтен фронт буенча чигенгән буталчык чорда сугышырга туры килә. Шуның өчен дә, бабамның сугыш юлы озын булмый, ул шушы сугышларның берсендә авыр яраланы, сыңар кулын югалта.

Госпитальләрдә дәваланганнан соң, 1941 елның августында демобилизацияләнеп кайта. Чепья районы кулланучылар җәмгыятенең Шода сельпосында склад мөдире булып эшли башлый. 1942 елның августында Кургем авыл Советы рәисе итеп сайлана.1943 елның августыннан 1950 ел башына кадәр Арбор авылы Советы рәисе була һәм гаиләсе белән бөтенләйгә Арборда төпләнеп кала. (Бу авыр һәм катлаулы чор турында хезмәтемнең алдагы бүлегендә яктыртырга тырышырмын). 1950-1953 елларда М. Зәкиев "Заготскот"ның Чепья кабул итү пунктының бухгалтеры, Чепья хәзерләүләр конторасы директоры булып эшли.

1953 елның мартында Мәгъсүм Зәкиев Нөнәгәр авылындагы Вахитов исемендәге колхозның рәисе итеп сайлана. Ул монда 1956 елның җәенә кадәр эшли, колхоз шушы чорда шактый күренекле нәтиҗәләргә ирешә һәм ул, колхозның рәисе буларак, бер төркем хезмәт алдынгылары белән Мәскәүгә, Бөтенсоюз халык хуҗалыгы казанышлары күргәзмәсенә бара.

Мәгъсүм бабай 1956-1958 елларда "росглавмолоко" идарәсенең Татарстан Республикасы трестының Чепья (Түнтәр) сөт-май заводын җитәкли, 1958 елның июлендә Чепья сельпосының чәй йорты мөдире итеп билгеләнә. Әмма сугыш яралары, үтә тынгысыз елларның газаплары үзен елдан-ел ныграк сиздерә. Шулар нәтиҗәсендә Мәгъсүм Зәкиев бик иртә, 43 яше тулыр-тулмас, 1959 елның 24 январенда вафат була. Аның җәсаде Арбор авылы зиратында дәфенләнгән.

**Бүлек 3. Бөек Ватан сугышы елларында Авыл Советы эшчәнлеге**

Бабабыз Зәкиев Мәгъсүм Зәки улы илебез өстендә куркыныч афәт- Бөек Ватан сугышы чорында берничә авылда хезмәт итә. Ул 1942 елның августында Кургем авыл Советы рәисе итеп сайлана. 1943 елның августыннан 1950 ел башына кадәр Арбор авылы Советы рәисе була. Үтә авыр һәм катлаулы чорда матди яктан гаять юксыл хәлдә булган авылда Совет эшенә җитәкчелек итәргә туры килә.

Әлеге елларда авыл Советының эшчәнлеген сыйфатлаучы кайбер сәхифәләргә тукталып китик.

Чепья районына Балтик буе республикаларыннан, Мәскәү тирәсеннән, Россиянең көнбатыш төбәкләреннән эвакуацияләнгән 2283 кеше китерелә. Алар ике агым булып эшелоннар белән Шәмәрдән станциясенә киләләр. Шушыннан аларны бүлгәләп атлар белән районыбыз авылларына тараталар. Менә шушы мөһаҗирләрне алып кайту, урнаштыру, аларның көндәлек мәнфәгатьләрен кайгырту һәм башка мәсьәләләрне үз өстенә авыл Советларына алырга туры килә. Еш һәм даими уздырылган авыл Советы башкарма комитеты утырышларында аларны азык, кием-салым, утын белән тәэмин итү, дәвалау, сәламәтләрен эш белән тәэмин итү, балаларын укырга йөртү мәсьәләләре еш каралган, моңа колхоз җитәкчелеге, укытучылар, авыл халкы һәм авыл активы җәлеп ителгән.

1941 елның 25 ноябрендә район Советы башкарма комитеты боерыгы белән Кызыл Армиягә 2 ат, сбруйлар, арбалар, бау, капчык, чиләк, чүкеч һ.б. туплап җибәрү заданиесе җиткерелә. Мондый заданиеләр алга таба елга берничә мәртәбә эзлеклелек белән кабатлана. Болар өстенә фронттагылар өчен җылы киемнәр җыю, бәйрәмнәргә бүләкләр җибәрү кампанияләре уздырыла. Ел саен җиңү фондына заемнар чыгарыла, лотореялар уздырыла. Танк колонналары, самолет эскадрильялары, корабльләр төзү өчен халыктан акча җыела. Урман кисү, торф чыгару, оборона корылмалары төзү эшләренә кешеләр, атлар озатыла. Бу эшләр нигездә кыз балалар, яшь хатыннар, яшүсмерләр өстенә төшә. Квартал саен авыл Советларына оборона предприятиеләрендә, шахта-рудникларда эшләү өчен кешеләр җибәрү, ФЗӨләргә уку өчен яшүсмерләрне озату

планнары куела. Кешесез калган рус өлкәләренә вербовка тәртибендә гаиләләре белән кешеләр озатыла...

Ай саен кабатланып торган бу заданиеләр, планнар, кампанияләр тулысынча авыр хезмәттән, ачлык-ялангачлыктан миңгерәүләнү дәрәҗәсенә җиткән чарасыз авыл кешеләре иңенә төшкән. Болар өстенә тоташ кул көченә нигезләнгән колхоз эшләрен үз вакытында башкарырга кирәк бит әле. Авыл кешесенең җелеген суыра торган әлеге чараларны оештыруның башында да авыл Советлары торган. Аларның хезмәтенең никадәр газаплы булуын күзаллау өчен башка сүзләр кирәкмидер дә инде...

Авылдагы бик күп эшләр – җәен кырда эшләү, кышын фермаларда дежур тору, фронт өчен акча, җылы кием туплау, заемга кул куйдыру, ачтан егылган атларны аякка бастыру өчен халыктан бәрәңге җыйнау, агитатор буларак халыкара хәлләрне, сугыш хәбәрләрен үзләренә беркетелгән бригадаларга җиткерү кебек бик күп игелекле эшләрне оештыручылар да шул ук авыл Советлары булган. Сугышның афәтле нәтиҗәсе буларак авылда күп санда ятим балалар, инвалид фронтовиклар, авырулар, мохтаҗ гаиләләр барлыкка килгән, аларның саны елдан ел арта барган. Алар турында кайгырту, мөмкин булган ярдәмне оештыру да шул ук авыл Советлары иңенә төшкән. Мәсәлән, 1944 елның июлендә эшкә яраксызларны, мохтаҗларны, фронтовик гаиләләрен тукландыру пунктлары ачыла башлый. Арбор авылында да 100 кешегә исәпләнгән шундый пункт булдырыла. Ике тапкыр ашау әзерләү өчен һәр кешегә көнгә 200 грамм он, 200 грамм сөт, 10 грамм май, 10 грамм тоз бүлеп бирелгән. 24 июльдә бер ай эшләгәннән соң пунктның эшен тагын 5 көнгә озайтырга дигән карар чыгаралар. Фронтовик гаиләләренә өстәмә икмәк бирелгән. Тоташ мохтаҗлык чорында авыл Советы хезмәткәрләренә бу четерекле эшне гадел итеп оештыру өчен чын мәгънәсендә йөрәк җылысын бирергә туры килгән.

Авылда сугышка кадәр үк авыл Советы бинасында телефон һәм радиоалгыч булган. Тыл ветераны Нәсимә әби бик кызыклы бер истәлеген сөйләде. 1945 елның 10 маенда ул авыл Советында дежурда булган. *“Мин авыл Советы бинасының болдырында идем. Көтмәгәндә минем янга бик тә шатланган һәм дулкынланган авыл Советы рәисе Мәгъсүм Зәкиев йөгереп чыкты һәм әле генә радиодан сугышның Советлар Союзының җиңүе белән тәмамлануын хәбәр итүләрен әйтте, миңа тиз генә колхоз рәисләрен, мәктәп директорын чакырырга кушты. Алар килгәч халыкны җыеп митинг ясадык. Ул халыкның шатланулары онытылырлык кына түгел иде.*

**Йомгаклау**

Нәсел шәҗәрәсеннең башка - хәзерге чорга якынрак буын вәкилләре турында да күп мәгълүмат биреп, кызыклы хезмәт язарга булыр иде. Мәсәлән, әниемнең этисе – Зәкиев Билсур Мәгъсүм улы - минем бабам турында. Ихластан авылны, аның кешеләрен яраткан, гомере буе алар мәнфәгате өчен хезмәт иткән кеше ул. 25 ел ел колхоз җитәкләү дәверендә бөтен эшләгәне, уйлаганы, кылганы – авылны үстерү, кешеләргә яхшылык эшләү, тормыш шартларын яхшырту булды. Күпме төзелешләр башкарылды, күпме үзгәрешләр кичерелә ул чорда. Авыл тарихына изге эшләре, киңәшләре, мәрхәмәтлелеге белән кереп калган җитәкче ул.

Билсур бабаемның улы, әниемнең бертуган абыйсы Зәкиев Роберт Билсур улы турында язарга мөмкин иде. Игелекле хезмәтләре, киң күләмдә башкарган хәйриячелек эшләреннән тыш, абыем ел саен мәктәбебезгә зур ярдәм күрсәтә: кабинетларны җиһазлый, ремонт-яңарту эшләрендә булыша. Аның ярдәмендә Арбор авылында өр яңа һәйкәл, балалар мәйданчыгы сафка басты. 2007 елдан башлап, һәр елны район мәктәпләрендә укучы көрәшче малайлар арасында, этисе Билсур Зәкиев истәлегенә татарча көрәш бәйгесе уздыра.

Әмма үземнең бу өлкәдә беренче хезмәтемне Мәгъсүм бабайга багышлыйсым килде, чөнки нәкъ менә ул - безгә билгеле булган җиденче буын вәкиле, әлеге нәселнең бер тармагын Арбор авылы белән бәйли. Туган авылыбызда Зәкиевлар нәсел

агачы шуннан соң үсеп чыга, тармаклана, хәзер инде күп тармаклы бу нәсел үзенең илгә-көнгә билгеле кыз-уллары белән горурлана ала.

Киләчәктә нәселебез шәҗәрәсен тирәннән өйрәнүне үземнең бурычым дип саныйм, чөнки шәҗәрәләр безгә якын кешеләребез, үз нәселебез аша халкыбызның үткән юлын, чал тарихын сөйли. Шәҗәрә агачын, буыннар тезмәсен, гаилә тарихын төгәл эшләү өчен төрле мәгълүмат туплау шактый вакыт сорый, тапкан материалларны җентекләп тикшерүне таләп итә. Шәҗәрә төзү – шәҗәрә агачы һәм буыннар тезмәсен барлау белән генә чикләнми. Нәсел, гаилә тарихы ул илнең дә тарихы. Ул һәр кешенең эшенә һәм тормыш юлына, күпсанлы кардәш-ыруның бәйләнешләренә ачыклык кертә. Гаилә тарихы аша кеше үзенең кемлеген, чыгышын, бу якты дөньяга нинди эшләр башкарырга килгәнлеген, туган нигезенең үткәнен, халкының тарихын, килеп чыгышын ачыклый ала.

Үткәнен белмәгәннең киләчәге юк. Димәк, шәҗәрәсе билгеле булган, үткәненә ихтирамлы халык – игелекле киләчәккә лаек Халык! Шәҗәрә – нәсел агачы дигән сүз. Агачларыбыз корымасын, мәңге яшел булсын! Бу исә үзебездән тора.


*Кулланылган әдәбият*

1. Әхмәтҗанов М. Татар шәҗәрәләре. -Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1995.

3. Бөек Ватан сугышы еллары турында. (Мәктәп музеенда саклanучы язма хатирәләр)

4. Зәкиевлар архивы язмалары

5. Мөхәммәтшин Г. С. Урбар.-Казан: “Идел-Пресс”, 2013

6. Идрисова Нәсимә хатирәләре


## “СЕРЛЕ САНДЫК” ДӘРЕСТӘН ТЫШ ЭШЧӘНЛЕК ПРОГРАММАСЫ


*Мөбәрәкова Гөлнара Рамазан кызы,*
*“Ядегәр авылы Г.Г. Гарифуллин исемендәге*
*урта гомуми белем бирү мәктәбе” нең*
*башлангыч сыйныфлар укытучысы*


"Хәтердән башка йолалар, тәрбиядән башка рухи хәзинә, рухи хәзинәдән башка шәхес, ә шәхестән башка халык - тарихсыз"- дип әйтелә халыкта.

Бала күңелен ап-ак кәгазь белән чагыштыралар. Шул кәгазьгә ничек итеп матурлык, шәфкатьлелек бөртекләрен чәчәргә соң? Әлбәттә, әдәбият-сәнгать аша. Әдәбият, сәнгать белән кызыксынган, китапларны чын күңеленнән яратып укыган баланың белеме дә тирәнрәк, күңеле дә байрак була. Аның күркәм эшләр башкарырга омтылышы да көчәя.

Кешеләрнең үз- үзләрен тоту кагыйдәләр җыелмасын тәшкил итүче сөйләм этикеты халыкның мәдәнилек дәрәҗәсен билгели торган иң мөһим өлешләрнең берсе булып тора. Сүз сәнгате - халык байлыгы, ул аның тормышы, кызыксынулары, теләкләренә бәйле. Сәнгать, әдәбият телдән башка үсә алмый, чөнки тел – аралашу чарасы, көрәш коралы.

Безнең илдә һәр милләт кешесе үз телендә белем алырга, җәмәгать оешмаларында сөйләшүләр алып барырга һәм җыелышларда үз телендә чыгыш ясарга хокуклы. Тел – милләт байлыгы. Тел булмаса, милләт тә юк.

Әлеге программада башлангыч сыйныфта яңалык булып килеп кергән Федераль Дәүләт белем бирү стандарты буенча укытуда укучыларның дәрестән тыш эшчәнлеген оештыру буенча эш программасы урын алды.Укучылар эшчәнлеген оештыруның эстетик - сәнгать юнәлеше - театр түгәрәге эше тәкъдим ителә.

Бу түгәрәк укучыларның артистлык сәләтен, сәнгатьле сөйләм күнекмәләрен, логик фикерләүләрен үстерү максатыннан чыгып оештырыла. “Драма” түгәрәге, исеменнән үк күренгәнчә, театр, сәнгать, җыр-бию яратучы укучыларны туплый. Бу түгәрәк, шулай ук,

сәхнә серләренә төшенү, кулдан матур киемнәр әзерләү һәм зәвыклы киенү, тамашачылар алдында үз-үзеңне тотарга өйрәнү бурычларын үз эченә ала.

Түгәрәктә сәләтле балалар белән күмәкләп һәм индивидуаль эшләү урын ала. "Серле сандык" драма түгәрәге берләшмәсенә 7-10 яшьлек укучылар туплана. Дәресләр атнага 1 сәгатьтән елга 33-34 сәгать үткәрелә.

Максат:

Шәхес формалаштыруга юнәлтелгән технология аша укучыларда әдәбият-сәнгатькә мәхәббәт тәрбияләп, иҗади үсеш булдыру.

Бурычлар:

- укучыларны түгәрәк эшенә җәлеп итү, театр сәнгате белән кызыксыну уяту;
- сәнгать әсәрләренә мәхәббәт уяту;
- укучыларның артистлык сәләтен, иҗади талантларын күрә, уңышларга дәрт уята алуга ирешү;
- сәнгатьле сөйләм күнекмәләрен үстерү. сөйләгән чакта җаваплылык хисе тоярга, авазларны аңлаешлы итеп әйтергә өйрәтү;
- әдәби сөйләм кагыйдәләрен төшендерү, сүзне ничек әйтергә икәнен аңлату, әдәби әсәрне матур итеп укырга, дөрес аңларга, нык үзләштерергә әзерләү;
- халкыбызның милли традицияләре турындагы күзаллауны ныгыту;
- телебезнең матурлыгын күреп яратырга өйрәтү.

**Түгәрәкнең юнәлеше**

балаларның эстетик зәвыгын, иҗадифантазияләренүстерү;
- балаларнытрадицияләребезгәнигезләнгәнүзарааралашукультурасынаөйрәтү;
- балаларның милли теленбаету, туган ягыбызның гореф-гадәтләренә карата кызыксыну уяту, мәхәббәт тәрбияләү;
- сәләтлебалаларныачыклау.

**Көтелгән нәтиҗәләр һәм аларны тикшерү төрләре**

- уку елы ахырына матур итеп шигырь, әкият сөйләүләренә аларны сәхнәләштерергә өйрәнүләренә ирешергә;
- үз-үзләрен сәхнәдә матур, иркен итеп тота белүләренә ирешергә;
- укытучылар бәйрәме көнендә чыгыш әзерләргә;
- яңа елга әкият-тамашалар сәхнәләштерергә;
- 8 март һәм 23 февраль "Туган тел", "Нәүрүз" бәйрәмнәрендә чыгыш ясарга;
- Г.Тукай туган көнендә катнашырга, кечкенә күләмле хикәяләр, шигырьләр язарга;
- милли уеннар, биюләр, җырлар, нәфис сүз белән сәхнәдә чыгыш ясарга, концерт номерлары башкарырга.

**Программа эчтәлеге**

**I. Кереш (4 сәг.)**

Кереш дәрес. Укучыларны туплау, түгәрәкнең эш планы таныштыру. Инструктаж үткәрү.

**II. Яшь артистлар булырга әзерләнәбез (16 сәг.)**

Укучыларның сәнгатьле сөйләм күнекмәләрен үстерү. Сәхнә серләренә өйрәнү. Киенү-бизәнү осталыгы турында сөйләшү, сәхнәдә нәфис сүз белән чыгышлар карау.

Татар халык иҗаты белән танышу. Татар халык иҗатының үзенчәлекләрен билгеләү. Индивидуаль рәвештә җырлар, биюләр өйрәнү. Киемнәр әзерләү.

**III. Сәхнә уеннары (20сәг.)**

Татар халкының сәхнә уеннары, такмак, такмаза, тел шомарткычлар турында мәгълүмат бирү. Сәхнә өчен куелган уеннарны өйрәнү, сәхнәдә кую.

Балаларны парлы, күмәк биюләргә өйрәтү (бию элементларын кабатлау, көйгә басу, киемнәр әзерләү). Бәйрәмнәрдә чыгыш ясау.

**IV. Яңа ел бәйрәменә театраль тамашалар (20 сәг.)**

Яңа ел бәйрәменә әзерлек эшләре алып бару, киемнәр әзерләү. Яңа ел залын бизәү.

Спектакль өчен рольләр сайлау, кабатлау. Музыка сайлау. Декорация, киемнәр әзерләү. Яңа ел бәйрәмендә театраль тамашалар кую.

Җырлы-биюле, такмаклы уеннар өйрәнү. Төрле кичәләрдә уеннар белән катнашу. Бу уеннарны сыйныфташларына, кечкенә класс укучыларына өйрәтү.

**V. Сәламәт тәндә-сәламәт акыл (12 сәг.)**

Кызыклы спорт уеннары өйрәтү, күңелле ярыш-эстафета оештыру. Ярыш өчен киемнәр, эмблема әзерләү.

Спорт уеннары барышында тәнәфесләр вакытында катнашу өчен биючеләр әзерләү. (Кечкенә һәм өлкән группалар). “Сәламәтлек театры” әзерләү һәм чыгыш ясау.

**VI. “Мәктәп йолдызлары” театр атналыклары оештыру (31 сәг.)**

Театр атналыгы оештыру (атналык программасы аерым төзелә). “Мәктәп йолдызлары” атналыкларында катнашу өчен сәхнә әсәрләре сайлау.

Балалар өчен язылган җырлар тыңлау. Иң матур җырларны өйрәнү, сәхнәдә башкарырга (аерым, күмәк) әзерләнү. Җырга карата киемнәр сайлау.

Кызлар-малайлар белән вальс, заманча биюләр, милли биюләр өйрәнү.

**VII. Туган ягым – изге җирем. Экологик тема. ( 24 сәг.)**

Бүгенге көндә экологик проблема һәм аның әһәмияте. Табигатьне саклауга өлеш кертү: тирә-юньнең чисталыгын саклау, агачлар утырту, чишмәләрне чистарту, кошларга, җәнлекләргә карата мәрхәмәтле булырга кирәклеген төшендерү.

Экологик темага кичә, КВН, конкурслар үткәрү. “Кошларны таныйсыңмы? дип исемләнгән музыкаль театр-тамаша өйрәнү, чыгыш ясау.

**VIII. Йомгаклау (8 сәг.)** Түгәрәк эшенә анализ, йомгак

Барысы: 135 сәгать

I сыйныф - 33 сәгать

II сыйныф – 34 сәгать

III сыйныф – 34 сәгать

IV сыйныф – 34 сәгать

**1нче сыйныф өчен календарь-тематик планлаштыру**

| № | Бүлек исеме | әгатьләр саны | Тема | Үткәрү вакыты | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Календарь | ак ик |
| 1. | Кереш | | Укучыларны туплау. Түгәрәкнең эш планы белән таныштыру. Инструктаж үткәрү | | |
| 2. | Яшь артистлар булырга әзерләнәбез | | Без - яшь артистлар | | |
| 3. | | | Сөйләм этикеты. Тизәйткечләр. “Мин татарча сөйләшәм” | | |
| 4. | | | “Мин татарча сөйләшәм” Сәхнә серләрен өйрәнү. Видеоязмалар карау. Киенү-бизәнү осталыгы. Декорациянең роле. | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 5. | | | Якташ язучыларыбыз, шагыйрә, шагыйрьләребез белән аларның иҗаты белән танышу, шигырьләрен өйрәнү. Сәнгатьле сөйләм күнекмәләрен үстерү. | | |
| 6. | Сәхнә уеннары | 5 | Парлы бию. | | |
| 7. | | | Киемнәр әзерләү . “Кармакчы” парлы биюе. Музыкаль бизәлеш | | |
| 8. | | | Бишле бию. Музыкаль бизәлеш | | |
| 9. | | | Бишле бию. Музыкаль бизәлеш | | |
| 10. | | | “Кармакчы” , “Ал кирәк, гөл кирәк”җырлы уены. | | |
| 11. | Яңа ел бәйрәменә театраль тамашалар | 5 | Музыкаль бизәлеш | | |
| 12. | | | Яңа ел бәйрәменә такмак әйтеш уеннар | | |
| 13. | | | Яңа ел бәйрәменә такмак әйтеш уеннар | | |
| 14. | | | Яңа ел бәйрәмендә “Чыршы янында” тамашасы | | |
| 15-16. | | | Яңа ел бәйрәмендә “Чыршы янында” тамашасы | | |
| 17 | Сәламәт тәндә-сәламәт акыл | 3 | Җитезлеккә уеннар өйрәнү. “Өченче артык” | | |
| 18. | | | Драма уеннары “Карга, карга”, Буяу сатыш” | | |
| 19. | | | Саф һавада хәрәкәтле уеннар. “Каргалар, саесканнар”, “Карчыга һәм чебешләр” | | |
| 20. | “Мәктәп йолдызлары” театр атналыклары оештыру | 7 | Муса Җәлил шигырьләрен сәнгатьле уку буенча эш | | |
| 21. | | | Балалар өчен җырлар өйрәнү. “Гармунчы бит әтием” | | |
| 22. | | | Балалар өчен җырлар өйрәнү. “Иртән” | | |
| 23. | | | “ Шаян үрдәкләр” биюен өйрәнү | | |
| 24. | | | “Шаян үрдәкләр” биюен өйрәнү. “Әтиләр бәйрәме”ндә чыгыш ясау | | |
| 25. | | | Һади Такташның “Тәүфыйкълы песи” пьесасын сәхнәләштерүгә әзерлек | | |
| 26. | | | Һади Такташ “Тәүфыйкълы песи” пьесасын сәхнәләштерү. “8 нче матр бәйрәме”ндә чыгыш ясау | | |
| 27. | Туган ягым – изге җирем. | 6 | Әңгәмә “Экологик проблемалар турында сөйләшик” | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 28. | Экологик тема. | | “Туган ягым – яшел бишек” темасына рәсемнәр конкурсы | | |
| 29. | | | Әңгәмә “Туган авылым табигате” | | |
| 30. | | | Табигатькә экскурсия. Чишмәләрне чистарту. | | |
| 31. | | | Табигатькә экскурсия. Дару үләннәре җыю | | |
| 32. | | | Табигатькә экскурсия. Күбәләкләрне, бөҗәкләрне күзәтү | | |
| 33. | Йомгаклау. | 2 | Күңелле ял. Сәнгатьле итеп Г. Тукай шигырьләрен, А.Алиш әкиятләрен уку. Түгәрәк эшенә анализ, йомгак | | |
| | | | | | |

**2 нче сыйныф өчен календарь-тематик планлаштыру**

| № | Бүлек исеме | Сәгатьләр саны | Темалары | Үткәрү вакыты | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Календарь | ак ик |
| 1. | Кереш | 1 | Укучыларны туплау. | | |
| 2. | Яшь артистлар булырга әзерләнәбез | 4 4 | Артикуляция. | | |
| 3. | | | Артикуляция гимнастикасы. Тел гимнастикасы. Жестлар. Җор теллелек. | | |
| 4. | | | Сәхнәдә үз-үзеңне тота белү. Алып баручы. | | |
| 5. | | | Сөйләмдә көлү-көлдерү максатында ирония, юмор – мәзәк чаралары | | |
| 6. | Сәхнә уеннары | 5 | Парлы бию. | | |
| 7. | | | “Кармакчы”парлы биюе. | | |
| 8. | | | Музыкаль бизәлеш. | | |
| 9. | | | Киемнәр әзерләү. | | |
| 10. | | | Киемнәр әзерләү. | | |
| 11. | Сәламәт тәндә-сәламәт акыл | 3 | Спорт һәм бию. Гимнастик күнегүләр белән бию элементлары өйрәнү | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 12. | “Мәктәп йолдызлары” театр атналыклары | 13 | Спорт һәм бию. Гимнастик күнегүләр белән бию элементлары өйрәнү | | |
| 13. | | | Саф һавада хәрәкәтле уеннар. “Әбәкле”, Син йөгер!” | | |
| 14. | | | Дисктан һәм интернеттан балалар өчен җырлар тыңлау. | | |
| 15. | | | Балалар өчен җырлар өйрәнү. “Үрдәкләр” | | |
| 16. | | | Башкорт һәм татар биюләрен өйрәнү | | |
| 17. | | | Башкорт һәм татар биюләрен өйрәнү | | |
| 18. | | | Башкорт һәм татар биюләрен өйрәнү. | | |
| 19. | | | А.Алишның “Кәҗә һәм сарык” әкиятен сәхнәләштерүгә әзерлек | | |
| 20. | | | Әтиләр бәйрәменә концерт программасы әзерләү | | |
| 21. | | | А.Алишның “Кәҗә һәм сарык” әкиятен сәхнәләштерүгә әзерлек | | |
| 22. | | | Әтиләр бәйрәменә концерт программасы . А.Алишның “Кәҗә һәм сарык” әкиятен сәхнәләштерү | | |
| 23. | | | 8 нче март бәйрәменә концерт программасы әзерләү | | |
| 24. | | | 8 нче март бәйрәменә концерт программасы | | |
| 25. | | | Р.Рәлиева сүзләренә “Кайт карлыгач” җырын өйрәнү. | | |
| 26. | | | Р.Рәлиева сүзләренә “Кайт карлыгач” җырын өйрәнү. | | |
| 27. | Туган ягым – изге җирем. Экологик тема. | 6 | Әңгәмә “Бүгенге көн экологик проблемалары” | **1.04** | |
| 28. | | | “Туган авылым” темасына рәсемнәр конкурсы | **8** | |
| 29. | | | Туган як турында хикәяләр уку | | |
| 30. | | | Табигатькә экскурсия. Чишмәләрне чистарту | | |
| 31. | | | Табигатькә экскурсия. Күбәләкләрне, бөҗәкләрне күзәтү | | |
| 32. | | | Күзәтүләр буеча фикер алышу. | | |
| 33. | Йомгаклау. | 2 | Күңелле ял. Сәнгатьле итеп Фәнис Яруллин шигырьләрен уку | | |
| 34. | | | Түгәрәк эшенә анализ, йомгак | | |

**3 нче сыйныф өчен календарь-тематик планлаштыру**

| № | Бүлек исеме | Сәгатьләр саны | Темалары | Үткәрү вакыты | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Календарь | Фактик |
| 1. | Кереш | 1 | Укучыларны туплау. Түгәрәкнең эш планы белән таныштыру. Инструктаж үткәрү. | | |
| 2. | Яшь артистлар булырга әзерләнәбез | 4 | Дикция . Сәнгатьле сөйләм күнекмәләрен үстерү. Сәхнә серләренә өйрәнү. Татар халык әкиятләрен, “Каз өмәсе” күренешләрен сәхнәләштерүгә әзерлек. Видеоязмалар карау. | | |
| 3. | | | Киенү-бизәнү осталыгы. Декорациянең роле. “Каз өмәсе” күренешләрен сәхнәләштерү | | |
| 4. | | | Татар халык биюе (кызлар өчен) Татар халык биюе (малайлар өчен). | | |
| 5. | | | “Укытучылар көне”нә чыгыш ясау | | |
| 6. | Сәхнә уеннары | 5 | Сәхнәдә чыгыш ясауга әзерлек. Киемнәр әзерләү. Музыкаль бизәлеш. | | |
| 7. | | | Күмәк заманча бию өйрәнү. Драма уены “Курчак сатыш” | | |
| 8. | | | Күмәк заманча бию. Зиһен сынаш уены “Почта” | | |
| 9. | | | “Чәчәкләр биюе” өйрәнү. Драма уены “Кәбестә” | | |
| 10. | | | “Чәчәкләр биюе”. Җырлы-биюле уен “Әйт, күгәрчен” | | |
| 11. | Яңа ел | 5 | Башлангыч | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | бәйрәменә театраль тамашалар | | сыйныфлар өчен уеннар – ял сәгате. “Казлар-аккошлар”, “Аксак төлке” | | |
| 12. | | | Башлангыч сыйныфлар өчен уеннар – ял сәгате. “Парыңны тап”, “Җырлый торган өстәл” | | |
| 13. | | | Яңа ел бәйрәменә залны бизәү | | |
| 14. | | | Яңа ел бәйрәмендә “Кыш бабай таягы” әкият-тамашасы әзерләү | | |
| 15. | | | Яңа ел бәйрәмендә “Кыш бабай таягы” әкият-тамашасы. | | |
| 16. | Сәламәт тәндә-сәламәт акыл | 3 | Спорт һәм бию. Гимнастик күнегүләр белән бию элементлары өйрәнү | | |
| 17. | | | Гимнастик күнегүләр белән бию | | |
| 18. | | | Саф һавада хәрәкәтле уеннар. “Кем җитезрәк”, “Унике таяклы” | | |
| 19. | “Мәктәп йолдызлары” театр атналыклары | 8 | Дисктан һәм интернеттан балалар өчен җырлар тыңлау | | |
| 20. | | | Җыр өйрәнү “Кәләпүш”. Караокега кушылып җырлау | | |
| 21. | | | Вальс өйрәнү | | |
| 22. | | | Вальс өйрәнү | | |
| 23. | | | Вальс өйрәнү. “Әтиләр бәйрәме”ндә чыгыш ясау | | |
| 24. | | | А. Алишның “Койрыклар” әкиятен сәхнәләштерүгә әзерлек. | | |
| 25. | | | А. Алишның “Койрыклар” әкиятен сәхнәләштерүгә әзерлек | | |
| 26. | | | “Әниләр бәйрәме”ндә “Койрыклар” әкиятен сәхнәләштерү | | |
| 27. | Туган ягым – изге | 6 | “Кошларны танийсызмы?” | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | җирем. Экологик тема. | | музыкаль тамашаның эчтәлеге белән танышу. | | |
| 28. | | | “Кошларны танышсызмы?” музыкаль тамаша. Рольләргә бүлеп уку. | **8** | |
| 29. | | | “Табигать – тиңсез хәзинә”. КВН. | | |
| 30. | | | Табигатькә экскурсия. Чишмәләрне чистарту | | |
| 31. | | | Табигатькә экскурсия. Урмандагы кошларны тыңлау, күзәтү | | |
| 32. | | | Күзәтүләр буеча фикер алышу. Табигать турында хикәяләр уку. | | |
| 33. | Йомгаклау. | 2 | Күңелле ял. Сәнгатьле итеп Роберт Миңнуллин шигырьләрен, Л. Ихсанова хикәяләрен уку. | | |
| 34. | | | Түгәрәк эшенә анализ, йомгак | | |

**4 нче сыйныф өчен календарь-тематик планлаштыру**

| № | Бүлек исеме | Сәгатьләр саны | Темалары | Үткәрү вакыты | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Календарь | Фактик |
| 1. | Кереш | 1 | Укучыларны туплау. Түгәрәкнең эш планы белән таныштыру. Инструктаж үткәрү. | | |
| 2. | Яшь артистлар булырга әзерләнәбез | 4 | Дикция . Сәнгатьле сөйләм күнекмәләрен үстерү. Сәхнә серләренә өйрәнү. Татар халык экиятләрен, “Аулак өй” күренешләрен сәхнәләштерүгә әзерлек. Видеоязмалар карау. | | |
| 3. | | | Киенү-бизәнү осталыгы. Декорациянең роле. “Аулак өй” | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | күренешләрен сәхнәләштерү | | |
| 4. | | | Әкиятләрдән өзекләр сәхнәләштерү. (Укучыларның иҗади эшләре.) | | |
| 5. | | | “Укытучылар көне”ндә чыгыш ясау | | |
| 6. | Сәхнә уеннары | 5 | Сәхнәдә чыгыш ясауга әзерлек. Киемнәр әзерләү.Музыкаль бизәлеш. | | |
| 7. | | | “Чәчәкләр аланында” сәхнә уенының эчтәлеге белән танышу. Рольләргә бүлеп уку. Сценарийны кабатлау. Киемнәр әзерләү. | | |
| 8. | | | “Чәчәкләр аланында” сәхнә уены | | |
| 9. | | | Башлангыч сыйныфлар өчен ял сәгате. “Зәлидә” уены | | |
| 10. | | | Күмәк заманча биюләр | | |
| 11. | Яңа ел бәйрәменә театраль тамашалар | 5 | Башлангыч сыйныфлар өчен уеннар – ял сәгате. Драма уены “Әби һәм карак” | | |
| 12. | | | Башлангыч сыйныфлар өчен уеннар – ял сәгате. “Тамчы-шоу”. Драма уены “Сукыр тәкә” | | |
| 13. | | | “Көмеш мөгез” экият-пьесаның эчтәлеге белән танышу. Хәрәкәтләр, музыка, киемнәр әзерләү. | | |
| 14. | | | “Көмеш мөгез” экият-пьесасы сценариен кабатлау. Хәрәкәтләр, музыка, киемнәр әзерләү. | | |
| 15. | | | Яңа ел бәйрәмендә “Көмеш мөгез” экият-пьесасы тамашасын күрсәтү | | |
| 16. | Сәламәт тәндә-сәламәт акыл | 3 | Ярыш-эстафетага әзерләнү. Эмблема. Киемнәр. Ярыш-эстафета | | |
| 1 | | | “Сәламәтлек | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 7. | | | театры”на әзерлек | | |
| 18. | | | “Сәламәтлек театры” үткәрү | | |
| 19. | “Мәктәп йолдызлары” театр атналыклары | 8 | Балалар өчен җырлар өйрәнү. “Балачак – бәхет иле”. Караокега кушылып җырлау. | | |
| 20. | | | “Чегән биюе” өйрәнү. Зиһен сынаш уен “Сыбызгы” | | |
| 21. | | | “Чегән биюе” өйрәнү. Драма уены “Ком калач” | | |
| 22. | | | “Гарәп биюе” өйрәнү. Зиһен сынаш уен “Дәшмә, сөйләшмә” | | |
| 23. | | | “Гарәп биюе” өйрәнү. “Әтиләр бәйрәме”ндә чыгыш ясау | | |
| 24. | | | С. Сәүбанованың “Арыслан буласым килә” театр-тамашаның эчтәлеге белән танышу. Рольләргә бүлеп уку. | | |
| 25. | | | С. Сәүбанованың “Арыслан буласым килә” театр-тамашасын сәхнәләштерүгә әзерлек | | |
| 26. | | | 8 нче март бәйрәмендә С. Сәүбанованың “Арыслан буласым килә” театраль тамашасын сәхнәләштерү | | |
| 27. | Туган ягым – изге җирем. Экологик тема. | 6 | “Хайваннарның күптөрлелеге” конкурсының эчтәлеге белән танышу. | | |
| 28. | | | “Хайваннарның күптөрлелеге” конкурсы | **1.04** | |
| 29. | | | “Экологик ассорти” | **8** | |
| 30. | | | Табигатькә экскурсия. Чишмәләрне чистарту. Агачлар утырту. | | |
| 31. | | | Табигатькә экскурсия. Урмандагы кошларны тыңлау, күзәтү, дару үләннәре җыю | | |
| 32. | | | Күзәтүләр буеча фикер алышу. Иншалар язу | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 33. | Йомгаклау. | 2 | Күңелле ял. Сәнгатьле итеп Рәшит Бәшәрнең шигырьләрен, “Ачык капка” хикәясен уку | | |
| 34. | | | Түгәрәк эшенә анализ, йомгак | | |

*Кулланылган әдәбият*


1. Алиш А. “Хикәяләр һәм әкиятләр”, Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1991
2. Галиева Л.И., Баязитова Л.В. “Көч һәм рух тамырлары”Казан: “Мәгариф”, 2000
3. Зарипова Ф.Я.”Могҗизалы мәктәп сәхнәсе”, Казан: “Мәгариф”, 2003
4. Казыйханов В. “Әхлак дәресләре”, Яр Чаллы: “Иҗат”, 1998
5. Мазин И. “500 загадок для детей”, Москва: ООО “ТЦ Сфера”, 2003
6. Мөҗәһит “Акыллыга сүз әйттем”, Казан: “Мәгариф”, 2003
7. Лях В.И. “Физкультура – минем дустым”, Москва: “Просвещение”, 2001, Казан: “Тарих”, 2002
8. Рахимов И.И “Хищные птицы и совы Татарстана”, Казань: Татполиграф, 1999
9. Фәйзи Җ. “Халык җәүһәрләре-күңелем кыллары”, Татарстан китап нәшрияты, 1987
10. Халикова Р.Ш. “Раушан көзге”, Казан: “Мәгариф”, 1993
11. Шаехова Р.К. “Ступеньки к творчеству”, Казань: “мастер Лайн”, 2000
12. “Татар балалар фольклоры”, Казан: “Хәтер”, 2009
13. “Татар халык әкиятләре”, Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1990
14. “Татар балалар әдәбияты”серия “МК”, 19-20 том, Казан: “Тарих”, 2003
15. “Тылсымлы хикәяләр” серия “МК”, Казан: “Тарих”, 2003
16. “Татар халык уеннары”, серия “Энҗе чәчтем, энҗе җыям”, Казан: “Мәгариф”, 2003
17. “Татар халык иҗаты. Риваятьләр һәм легендалар”, Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1987
18. “Татар халык иҗаты. Табышмаклар”, Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1988
19. “Татар халык җырлары”, Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1987
20. “Татарские танцы”, Казань: “Магариф”, 2002


## АНГЛИЯДӘН КИЛГӘН КУНАКЛАР ТЕКСТЫ


*Гөлназ Сабирҗан кызы Мөхәммәтҗанова,*
*Алабуга шәһәре 10нчы мәктәбе*
*Алабуга районы*


Предмет : Татар теле
Сыйныф: 6
*Дәрес тибы:* Белем һәм күнекмәләрне комплексы куллану дәресе (ЛГКК)
Дәрес максатлары:
1.Укытучы өчен:
Белем бирү максаты (дәреснең предмет нәтиҗәсе):
- текстны аңлап уку, Татарстан Республикасына карата яхшы мөнәсәбәт тәрбияләү;
Үстерү максаты (дәреснең метапредмет нәтиҗәсе):
- парларда һәм күмәк эшли белү;
-әңгәмәдәшеңнең фикерен тыңлый, арлаша белү күнекмәләрен формалаштыру.

*Тәрбия бирү максаты (дәреснең шәхси нәтиҗәсе):*

*-кунакчыллык, чит төбәк, башка ил вәкилләренә карата хөрмәт хисләренә уңай йогынты ясау.*

*2. Укучыларга җиткерелә торган белем бирү максаты* (дәреснең предмет нәтиҗәсе):

- Татарстан Республикасына карата яхшы мөнәсәбәт тәрбияләү.

*Җиһазлау:* Р.З.Хайдарова, З.Р.Назипова “Күңелле татар теле” дәреслеге (92-95нче битләр), дәрескә әзерләнгән презентацион материаллар, ТР һәм Англиянең дәүләт символлары һәм карталары, глобус, ситуатив күнегүләр язылган карточкалар.

**Дәрес барышы:**

I.ОЕШТЫРУ, МОТИВЛАШТЫРУ

1) Исәнләшү:

- Исәнмесез, укучылар! (Укучылар җавабы)

- Хәлләрегез ничек? (Укучылар җавабы)

- Рәхмәт, яхшы, утырыгыз.

2) Бүген дәрестә кем дежур? (Дежур укучы рапорты).

II. БЕЛЕМНӘРНЕ АКТУАЛЬЛӘШТЕРҮ

1. Өй эшен тикшерү:

92нче биттәге 3нче күнегү:

- Дәрестә өйрәнгән яңа сүзләрне яттан сөйләү,

- 3нче күнегүдәге җөмләләрнең тәрҗемәсен тыңлау (1 укучы җөмләне укый, икенчесе тәрҗемә итә).

- Яңа сүзләр белән төзелгән җөмләләрне тыңлау (берничә укучы).

2. Белемнәрне тигезләү:

1)Прослушайте и укажите, что изменено во втором предложении каждой пары:

1.Татарстан – бай дәүләт. – Татарстан – зур дәүләт.

2.Татарстанның үз флагы бар. – Татарстанның үз гербы бар.

3.Татарстан флагында өч төс бар. – Татарстан флагында өч төс бар: яшел, ак кызыл.

III. УКУ МӘСЬӘЛӘСЕН КУЮ

**1.** Дәреснең темасын билгеләү.

1. Ә хәзер игътибар белән тыңлыйбыз. (слайдта ТР, аннан соң Англиянең дәүләт символлары һәм картасы күрсәтелә, ике дәүләтнең гимннары яңгырый) СЛАЙД 1-2

- Рәхмәт, урыннарга утырабыз. Без нәрсә тыңладык, укучылар? (җаваплар) Татарстан гимныннан соң тагын нинди дәүләт гимны яңгырады? (җаваплар) Ә хәзер дәреснең темасын билгеләп карыйк әле. (укучыларның фикерләре тыңлана)

2. Максат билгеләү.

- Әйе, без бүген “Англиядән килгән кунаклар” хикәясе белән танышырбыз. Үзегезгә нинди максатлар билгеләрсез? (укучыларның фикерләре тыңлана, кирәк буллса, төзәтелә)

IV. УКУ МӘСЬӘЛӘСЕН АДЫМЛАП ЧИШҮ ЭШЕ

1. Телдән эшне оештыру.

- Укучылар, экранга карагыз әле, минем электрон почтама видео-хат җибәргәннәр.Тик мин бер нәрсә дә аңламадым. СЛАЙД 3. (видеоязма: “ Хәерле көн, хөрмәтле татарстанлылар, кадерле балалар! Без Англиядән сезгә кунакка килергә, сезнең белән якыннан танышырга телибез. Сезнең гореф-гадәтләрегез, традицияләрегез турында беләсебез килә. Сез безгә ярдәм итәрсез дип уйлыйбыз.”)

-Укучылар, мин инглиз телен белмим. Миңа ярдәм кирәк. (бер укучы Англия кунагының сүзләрен татарчага тәрҗемә итә)

- Инглизләр инде Татарстанга килеп тә җиткәннәр. Очрашу ничек узды икән? Моны хикәяне укыгач белербез. Хәзер барыбыз да дәреслекләрдә 92нче битне ачабыз һәм 7нче күнегүне карыйбыз. (бер укучы биремне укый, алга таба 3 укучы хикәяне укый, аннан соң кыскача эчтәлекне 2-3 укучы сөйләп бирә)

2. Үзләштерүне беренчел тикшерү.

- 7нче күнегүнең беремендә нинди сорау куелган иде? (1 укучы кабатлый: Кунаклар нинди теләкләр әйтәләр?)

-Англиядән килгән кунаклар нинди теләкләр белдерделәр соң?

- Ничек уйлыйсыз, очрашу яхшы уздымы? (юк, чөнки укучылар сорауларга җавап бирә алмадылар)

-Укучыларга нишләргә кирәк иде?

- Хәзер, әйдәгез, 94нче биттәге 9нчы күнегүне эшләп алыйк. (бер укучы биремне укый, укучылар чиратлап, раслауларны укыйлар һәм кайсы дөрес икәнлеген әйтәләр)

V. ФИЗМИНУТ

- Ә хәзер, укучылар, бераз ял итеп алыйк.

- Прослушайте внимательно и встаньте, если слово не относится к прочитанному нами тексту, и, наоборот, сядьте, если слово подходит по смыслу к тексту «Англиядән килгән кунаклар»

- Киткән, мәктәп, сабантуй, очрашу, авыл, көтелгән кунак, русча әкият, инглизчә җырлар, түгәрәк өстәл, Германия кунаклары.

- Булдырдыгыз, укучылар, урыннарга утырыгыз, дәресне дәвам итәбез..

VI. НЫГЫТУ ЭШЕ, ҮЗАЛЛЫ ЭШ

1. Тема буенча мөстәкыйль күнегү эшләүне оештыру.

- Хәзер дәфтәрләрне ачабыз, бүгенге числоны һәм теманы язабыз.

- 94нче биттәге 10нчы күнегүне буенча эшләп алыйк әле. (Бирем: җөмләләрнең эчтәлеге буенча сораулар төзү: 1 укучы биремне укый, 1-2нче җөмләләр буенча 1нче өстәлдә утыручылар, 3-4нче җөмләләр буенча 2нче өстәл, 5-6нчы җөмләләр буенча 3нче өстәлдәгеләр сораулар төзеп, күнегүне дәфтәрдә мөстәкыйль рәвештә эшлиләр, аннан соң эшләр тыңлана)

- 11нче күнегү буенча җөмләләрне киңәйтеп язу. 1 минут вакыт бирелә (1 укучы биремне укый, кәгазьдә төркемләп эшлиләр: 1нче укучы җөмләне күчереп яза, 2нче укучы бер сүз өстәп киңәйтә.... соңгы укучы барлык җөмләләрне укып чыга. 3 өстәлгә 3 җөмлә.)

2. Ситуатив күнегүгә чыгару.

- Укучылар, күз алдына китерегез әле. Бүген безнең мәктәпкә Англиядән кунаклар килделәр, ди. Алар Татарстан турында белергә телиләр. Менә бу карточкаларны алыгыз, ситуатив биремнәрне укыгыз һәм җаваплар әзерләгез. (укучыларга ситуатив күнегүләр язылган карточкалар өләшенә, уйларга 30секунд вакыт бирелә, җаваплар тыңлана)

- Ә глобустан Англияне табып карыйбызмы? ( укучылар өстәл уртасында торган глобустан Англиянең башкаласы Лондонны табып күрсәтә)

- Кунаклар безгәерактан килгәннәрме?

- Әйе, Англия бездән бик ерак шул. Димәк без кунакларны ничек каршы алырга тиеш? (укучыларның җаваплары тыңлана)

- Рәхмәт, укучылар, булдырдыгыз. Ә хәзер көндәлекләрне ачып, өй эшен язып алыгыз.

VII. ӨЙ ЭШЕ БИРҮ

- 95нче биттәге 14нче күнегү буенча әзерләнергә:

1) Дустыңа сораулар бирергә (бу биремне, кемнәр бүгенге дәресне бик яхшы үзләштермәдем дип уйлый, шулар эшли)

2) “Англиядән килгән кунаклар” хикәясенең эчтәлеген белергә (бу бирем буенча текстны яхшы аңладым дип уйлаучы укучылар әзерләнә)

3) Татарстан турында сөйләргә әзерләнергә (бүгенге дәрестә барысын да яхшы эшләдем, тулысынча аңладым дип уйлаганнар яхшылап үзебезнең республикабыз турында сөйләргә әзерләнеп килә).

VIII. РЕФЛЕКСИЯ (ЙОМГАКЛАУ)

- Укучылар, без дәрескә нинди максатлар куйган идек? (максатларны искә төшерү)

- Без максатларга ирештекме? (җавапларны тыңлау)

- Бүгенге белемнәрне тормышта кайда кулланырга була? (җавапларны тыңлау)

IX. БӘЯЛӘҮ

- Укучылар, бүгенге дәрес өчен кемнәр үзләренә “5” билгесе куя? (кул күтәрәләр)

- Ә кем үзенә “4”ле куярга тели? (кул күтәрәләр)

- ... , син ни өчен үзеңә “4” куясың? “5”ле алу өчен нәрсә җитеп бетмәде дип уйлыйсың?

- ..., син ничек уйлыйсың, ... ни өчен үзен “5” билгесе белән бәяләде?

- Рәхмәт, укучылар, мин сезнең фикерләрегез белән килешәм (килешмим). Әлеге билгеләрне журналга куярмын.

- Дәрес тәмам, сау булыгыз!

## ЛЕКСИКОЛОГИЯ БҮЛЕГЕН КАБАТЛАУ

*Мөхәрләмова Зөбәрҗәт Малик кызы,*
*Сабабаш төп гомуми белем бирү мәктәбенең*
*Саба районы*

**Тема:** лексикология бүлеге буенча кабатлау дәресе ( дәрес-сәяхәт, 5 нче сыйныфта татар теле)

**Максат:** : 1) “Лексика” бүлегендә үтелгән материалны гомумиләштереп кабатлау, укучыларның белемнәрен системалаштыру;

2) Укучыларның үзбелемнәрен һәм иҗади активлыгын үстерү

3) Туган телбезне өйрәнергә кызыксыну уяту

**Универсаль уку гамәлләре формалаштыру:**

*Шәхси:*уку эшчәнлегендә үзбәя куя белү.

*Танып белү:* эшкә максат кую, максатка ирешү юлларын эзләү; тиешле кагыйдәләрне билгели белү.

*Регулятив:* тиешле кагыйдәләрне файдалана белү.

*Коммуникатив:* башкаларга юл куя белү, парларда һәм төркемнәрдә эшләгәндә уртак фикергә килү;

**Җиһазлау:** 1) “Аңлатмалы сүзлекләр” 1-3 том, “Русча-татарча сүзлек”, “Татар энциклопедиясе”, “Фразеологик әйтелмәләр”, “Орфография” һ.б.; презентация

**Материал**:

1. Вәлиева Ф.С., Саттаров Г.Ф. Урта мәктәп һәм гимназияләрдә татар телен укыту методикасы. – Казан: “Раннур” нәшрияты, 2000.

2. Сафиуллина Ф.С., Зәкиев М.З. Хәзерге татар әдәби теле. – Казан: Мәгариф, 1994. – Б. 24-142.

3. Әхмәтшина Ф. Омонимнар, синонимнарны өйрәнү // Мәгариф, 1998. – № 8. – Б. 48-49.

4. Хәйруллин М. Лексикабызда чит тел сүзләре // Мәгариф, 1998. – № 9. – Б.82-83.

5. Абдрәхимова Я.Х. Татар теленнән бәйләнешле сөйләм үстерү дәресләре. 5-7. – Казан: “Мәгариф” нәшрияты, 2003.

6. Харисова Ч.М. Татар теле. Анализ үрнәкләре. – Казан: “Мәгариф” нәшрияты, 2009.

7.Хәсәншина Р. Г. Татар теле дәресләре, 5 сыйныф: методик кулланма/ - Казан: татар. Китап нәшрияты, 2015.

**Дәрес тибы :** белемнәрне кабатлау, системага салу, ныгыту

Дәрес барышы.

**1.Оештыру- мотивлаштыру этабы.**

**Укытучы**.Хәерле иртә, укучыларым!

**Укучылар**. Безне яңа эшләр белән
Яңа көн көтә.

Сәлам сиңа, өр-яңа көн,

Хәерле иртә!

**Укытучы.** Бер-беребезгә карап елмаештык. Утырабыз. Бәяләү карточкалар алдыгызда торсын, һәр эшегезне бәяләп барырга онытмагыз.

Минем кулымда искитмәле матур кәрҗин бар. Ләкин аның эче буш. Әйдәгез, аны сүзләр белән тутырыйк әле. Матур кәрҗиннең эченә нинди сүзләр салыр идегез, укучылар?

**Укучылар.** Кәрҗине матур булгач, аның эченә дә матур, яхшы, күңелне күтәрә торган сүзләр генә саласы килә.

**Укытучы.** Сезнең алдыгызда ак кәгазь ята. Карандаш алып, сул кулыгызны рәсемгә төшерегез (сулагай язучы балалар уң кулларын) дә кемнең кулы икәне билгеле булсын өчен, исемнәрегезне язып куегыз. Ә хәзер чылбыр буенча иптәшләрегезгә тапшырабыз. Сыйныфташыгызда сез күргән иң матур берничә сыйфатын “кул эченә” язып куябыз һәм киредән иптәшләребезгә җибәрәбез.

**Укытучы.** Әйтегез әле, укучылар,үзегезне ничек хис итәсез?

**Укучылар.** Кәефләр күтәрелде,канатлар үскәндәй булды, тагы да яхшы буласы килә, кемгәдәдер булышасы килә һ.б.

**Укытучы.** Бик яхшы. Мондый хисләр кичерергә нәрсә ярдәм итте безгә?

**Укучылар.** Сүзләр ярдәм итте.

**Укытучы.** Сүз ул- аңлашу, аралашу чарасы.Телне өйрәнү беренче чиратта сүздән башлана. Без бит үзебезнең тормышыбызны телдән башка күз алдына да китерә алмыйбыз. Сөйләм вакытында бик күп сүзләр арасыннан, теге яки бу фикерне әйтү өчен, кирәклесен сайлап алырга, аны урынлы куллана белергә тиешбез. Дөрес һәм матур итеп сөйли белү-кешенең гомуми культуралылыгының бер билгесе. Моңа ирешү өчен сөйләмеңә игътибар итеп тору, телгә таләпчән була белү кирәк. Кызганыч ки, тормышта безгә еш кына сөйләм культурасының бозылу күренешләре белән очрашырга туры килә.

**2. Өй эшләрен тикшерү.**

**Укытучы.** Сезгә өй эше итеп нәкъ тә менә шушы: сөйләм культурасының бозылу күренешләрен күзәтергә кушылды. Сез телебез сакчылары буларак, нинди күренешләр белән очраштыгыз?

**Укучылар. 1 нче төркем.**

Безнең төркем олы буын кешеләрнең сөйләмен тикшерде. Олы буын вәкилләренең төп сөйләм үзенчәлеге – рус сүзләре татар фонетик системасына ярақлаштырып әйтелә: *Бүген бүлнистә пинсәнирләр күне булган; Тилифун шалтырый; Куфе эчәсеңме?; Карманыма салып куй;*

Олы буын кешеләре (Ц),(Э) авазларын (ТС),(с),(И) авазлары белән алмаштыра: *милиция-милитсия.* Бу буын кешеләрендә бер үк сүзләрне төрле вариантта әйтү хас: *пинсе-пинсә.*

**2нче төркем**. Без урта буын кешеләренең сөйләменә игътибар иттек. Урта буын кешеләре телендә һөнәр атамалары төркеме аерыла: *бизнесмен; начальник,участок инспекторы, соиальный работник.*

Урта буын вәкилләре рус сүзләрен гадәттә рус теле нормаларына туры китереп куллана: *Балалар садикта калды; Служебный машина белән кайта; экологик чиста су; пособие алучылар күп; субсидия чыкты; лечиниесы килеште; ул самый главный кеше; документлар булырга тиеш* шулай да кайбер алынмаларда бер яки ике аваз үзгәртеп әйтелә: *бальниста, нәчәльник, ыштыраф;тавар,дитсат.*

**3нче төркем.** Безяшь буын вәкилләре сөйләмен тикшердек. Алар үз сөйләмендә иҗтимагый лексиканың фән өлкәсенә караган төшенчәләрен ешрак файдалана. Һәр алынма орфоэпик яктан төгәл әйтелә: *муниципаль районнар; профилактик чаралар яхшы узган; лекция сөйләделәр, модельләр уйладык, проектның асылын аңламыйм; сессияне яптык.* Яшь буын кешеләре сөйләмендәге бәяләү сүзләре рус телендәгечә кулланыла: *даже,ужас, нормально, супер.*

**Укытучы.** Әйе, ике телне буташтырып сөйләү матур күренеш түгел. Сез, укучылар, үз сөйләмегезгә һәрчак игътибарлы булырсыз.

Бүген дәрестә уңышлы эшләү өчен безгә төркемнәргә берләшергә кирәк. Һәрберегезгә сүз турында язылган мәкальләрнең өлешләрен бирәм. Сезгә мәкаль килеп чыгардай парларыгызны табарга кирәк. Сер итеп кенә әйтәм, дөрес тапкан очракта, төркемгә дүрт укучы берләшә.

*1) Аз\ сөйләсәң, \күп \ишетерсең.*

*2) Яхшы сүз - җанга дару,*

*Яман \ сүз\ - канга\ агу.*

**3. УМ кую.**

**Укытучы.** Менәэшләү өчен иптәшләр дә таптык. Бүгенге дәрескә максат һәм бурычлар билгелисебез бар. Кулымда җеп кисәге, сез аны нәрсә белән тәңгәлләштерер идегез( ассоциация)? Хәзер аңа төрле төстәге һәм төрле исемдәге 5 мәрҗән тезәм. Ни өчен? Бүгенге мәрҗәннең исеме ничек булыр? Төркемнәрдә фикерләшегез.

**1 төркем.** Җеп ул – тел белеме. Ә төрле төстәге 5 мәрҗән без өйрәнгән тел белеме тармаклары– морфология, синтаксис, фонетика, орфография , орфоэпия.

**2 төркем.** Бүгенге мәрҗәннең исеме лексика.

**3 төркем.**Бүген дәрестә лексик һәм сөйләм культурасы буенча алган белемнәребезне гомумиләштерербез, нәтиҗә ясарбыз.

**Укытучы.** Дөрес фикер йөртәсез, укучылар.

**4. УМ чишү.**

**Укытучы.**

Без бүген “Лексикология” утравына сәяхәткә китәчәкбез.Бу утрау белән таныштык инде. Иң беренче сәяхәтләребездә яңа белемнәр туплау өчен барган булсак, ә бу юлы исә, туплаган белемнәребез буенча сәяхәт кылырбыз. “Тел белеме” дигән диңгездә бу утрау бик зур һәм иң матурыдыр, мөгаен. Иң элек, бүгенге сәяхәтебезнең маршруты, белән танышыйк: (1нче слайд- болытлар астына өйрәнгән темалар яшерелгән)

Искергән сүзләр, фразеологик әйтелмәләр, профессиональ сүзләр, алынмалар, диалекталь сүзләр

Сез сәяхәт итәргә яратасызмы? Алайса, сәяхәткә кузгалыйк - вакыт уздырмыйк.

Алдан ук кисәтеп куям, сәяхәт вакытында тәртип булырга тиеш, иптәшләрегезгә авырлык килгәндә ярдәм итәрсез, һәрвакыт бердәм булыгыз! Шулвакытта гына сәяхәтебез күңелле һәм файдалы булыр.

**Терминнар причалы.** (2 слайд)Утрауның бер кырына килеп җиттек. Коры җиргә чыкканчы, терминнар причалында биремне үтәргә кирәк (ике ноктадан соң терминнарны язып куярга кирәк)

| 1 төркем | 2 төркем |
|---|---|
| 1. Бер-берсенә якын мәгънәле, ягъни мәгънәдәш сүзләр:<br>2. Капма-каршы мәгънәле сүзләр.:<br><br>3. Һәр төбәкнең үзенә генә хас җирле сөйләме:<br><br>4. Көндәлек һәм актив кулланылыштан төшеп калган сүзләр:<br>5. Тотрыклы, күчерелмә мәгънәдә килүче сүзләр<br>төзелмәсе: | 1. Бер үк авазлардан торган, ләкин мәгънәләре буенча төрле булган сүзләр:<br>2.Билгеле бер профессия кешеләре тарафыннан кулланыла торган сүзләр:<br>3.Башка телләрдән кергән сүзләр:<br><br>4.Телдә барлыкка килгән яңа сүзләр:<br><br>5. Тотрыклы, күчерелмә мәгънәдә килүче сүзләр<br>төзелмәсе: |

Биремнәрне тикшерү. Маршрут битенә үзләренә балл кую. (Биш җавапны белсәләр 5 балл, дүртне белсәләр 4 балл шулай дәвам итә.)

**Профессиональ сүзләр табы.**

Әкеренләп тауга күтәрелеп карыйк әле. Дөрес җавап биргән саен, өскә үрмәлибез. (3нче слайд)

**Бирем: бу сүзләр кайсы профессия кешесенә карый?**

1.ачык дәрес,педсовет, язма эшләр

2.ангина , рецепт, аспирин, компресс

3. графюра, киндер тарттыру, палитра

4) карбюратор, руль, тукталыш

5) Форвард, пенальти, гол, офсайд.

Биремнәрне тикшерү. Баллар кую

Таудан ничек төшәбез инде? Фуникелер белән .

**Сүзлекләр – безнең дуслар.**

Әкерен генә төшкән арада **сүзлекләр** турында сөйләшеп алыйк әле. Сезнең кулларыгызда төрле сүзлекләр бар. Аларга **реклама** ясагыз әле. Ә бер укучы аңлатмалы сүзлектән фуникулер сүзенең мәгънәсен карый. Укучылар сүзлекләр турында сөйлиләр.

**Диалекталь сүзләр болынында.**

**Бу** болында яшәүче кешеләрнең сөйләменә игътибар итик әле Ничек сөйләшәләр алар? (5слайд)

- Чишмәдән су алып кер, кәбам. Аннары иптәшләрең белән боз өстендә кәшәтаяк уйнарсыз.

- Хәзер бер бадия алып керәм. Әби, чәй эчәргә син киптергән кытырмачларны алсаң буламы?

- Ал, кәбам, ал.

Диалекталь сүзләрең мәгънәләрен аңлатыгыз.

Тикшерү. Баллар кую

- **кәбам-** иркәләп эндәшү сүзе **(**Ульяновск һәм Самара өлкәләре)

- **кәшәтаяк-** хоккей уены

- **бадия-** чиләк

- **кытырмач-** сохари

- **йөрәкмаем**-җаным

**Күп мәгънәле сүзләр белән омонимнар юл чатына килеп җиттек.**

Безгә омонимнар ягына чыгарга кирәк, анда җылырак, ял итеп тә алырбыз. Аның өчен башта бирелгән парлы сүзтезмәләр арасыннан омонимнарны сайлап алырга кирәк.

Тикшерү. Баллар кую.

**Юл башы-эш башы (**к.м.с)

**Кара акыл-кара сакал (**к.м.с)

**Утын яра- яра тирән** (омоним)

**Агач тамыры-сүзнең тамыры** (к.м.с.)

**Ана теле-кош теле** (к.м.с.)

**Төш күрү- биектән төш** (омоним)

**Чык төште-урамга чык** (омоним)

**Омонимнар бухтасында.**

**5. Динамик пауза.**

Монда җылы , рәхәт. Ял итеп алыйк. Физкульминутка.

Әйдәгез, юлыбызны дәвам итик.

**Искергән сүзләр музее.**

Рәсемнәргә карап кимендә искергән сүзләррнең тарихи төренә кергән 5 сүз язып куярга тиеш буласыз. Алар булырга мөмкин киемнәр, яки булмаса идарә итүчеләрнең исемнәре.

Тикшерү. Калфак, камзул, бишмәт, чабата, кафтан, хан, би, кам, патша.

Баллар кую.

**“Кабымлык” кафесында**

Бераз тамак ялгап алыр вакыт та җитте. Кафеда ниләр әзерлиләр икән? Меню белән танышып, алынма сүзләрнең астына сызып куегыз.

Меню(фр)

**Салатлар**

-Сыек майлы кыяр белән помидор.(итальян)

-Сыек майлы чөгендер, сарымсак.

**Ашлар**

Ит фрикаделькасы (нем) белән ярмалы аш

Тавык ите белән токмачлы аш

Окрошка (рус)

**Эчемлекләр**

Кофе (инглиз)

чәй

алма суы

куас (рус)

**Десерт (фр)**

Туңдырма

**Камыр ашлары**

Эремчекле бәлеш

өчпочмак

вак бәлеш

кыстыбый

печенье (рус)

**Фразеологик әйтелмәләр агымы. Мөстәкыйль эш.**

Ниһаять, сәяхәтебез ахырына җитте. Безгә бары тик фразеологик әйтелмәләр агымын гына үтәсе калды. Бирелгән фр.әйтелмәләрнең мәгънәләрен аңлатыгыз.

Балавыз сыгу- елау

**Утлы табага бастыру- ачулану**

**Таяк ашау-кыйнау**

**Агач атка атландыру- алдалау**

**Сүз көрәштерү- бәхәсләшү**

**6. Нәтиҗә ясау.**

**Укытучы.** Лексика бүлеген кабатлап чыктык. Сез бик белемле булуыгызны күрсәттегез. Белемнәрегезне модель формасында кагыйдәләр дәфтәренә сызабыз. Лексика бүлег нәрсәне өйрнә? Нинди бүлекләрдән тора? Сүзләр турында белгәннәрегезне күрсәтегез.

**7.Рефлексия.**

**Укытучы.** Сәяхәтебез шушының белән тәмам. Сезнең белән Лексика утравында күңелле сәяхәттә булдык. Әйдәгез, корабльгә утырабыз. Кайтыр юлга чыгар алдыннан сәяхәт буенча алган тәэсирләрегез белән уртаклашыгыз әле. Кемнәргә сәяхәт ошады? Нәрсәләргә өйрәндегез? Кайсы темалар сиңа авырдан бирелде? Нинди максатлар куйган идек? Максатларга ирештекме? Ничек? Нәтиҗәләр нинди? Тагы да нәрсәләр эшләргә тиешсез? Бүгенге белемне тормышта кайда һәм ничек кулланырга мөмкин? Синең бигрәк тә кайсы эшең уңышлы килеп чыкты? Алга таба нәрсә өстендә эшләргә кирәк?

**Укучылар җавабы.**

**Укытучы.** Кәрҗингә салган язуларыгызни киредән алыгыз, иптәшегезгә әйтәсе килгән тагы нинди сүзләрегез калды икән? Шуларны өстәп үзенә тапшырыгыз.

Ә хәзер балларны саныйбыз һәм билгеләр куябыз.

**Билге:**

**30-35 балл – «5»**

**25-29 балл – «4»**

**17-24 балл – «3»**

**7. Өй эше**. **Мәҗбүри**: 3 сүзгә лексик анализ ясарга.

**Ярым иҗади**: әдәби әсәрләрдән професиональ сүзләр язып алырга**Иҗади:** лексика бүлегенә10 сораулы тест төзергә.

**8. Йомгаклау.**

## АЛТЫНЧЫ ӘХМӘТГАЛИ УЛЫ ГАБДЕЛНУР

*Мухаметгалиева Илюза Ильфатовна, 3 сыйныф*
*Фәнни җитәкче - Нуриева Нурания Габдульбаровна,*
*Әтнә муниципаль районы Олы Мәңгәр төп гомуми белем бирүмәктәбе*

**Эзләнү эшенең максаты:**

1) Иске Мәңгәр авылы тарихы материаллары белән тирәнтен танышу;
2) Әхмәтгалиевлар нәселен зәрканчеләр нәселе буларак өйрәнү;
3) Авылдашлары, туганнары истәлекләрен барлау;
4) Нәселдән бирелүче һөнәрне дәвам итүчеләрне барлау.

**Эзләнү эшенең бурычлары:**

1) Иске Мәңгәр авылы тарихы турындагы белемнәрне арттыру.
2) Тарихыбыз, килеп чыгышыбыз турындагы эзләнү эшләрен алып бару күнекмәләрен булдыру һәм ныгыту.

**Эшнең актуальлеге**

Туган ил, туган як, туган авыл! Кеше кайда гына булмасын, ул иң беренче чиратта, эти-әнисен, туган ягын искә төшерә, алар белән бәйләнешле истәлекләрен яңарта. Ләкин алар турында уйланмау, әлеге төбәкнең, нәселеңнең тарихын, бүгенгесен белмәү, кызыксынмау - аны яратмауга тиң.

**1.Кереш.**

Авылыбыз бер ягыннан Симет елгасы, икенче ягыннан Каенсар урманы, Түгәрәк куагы, инеш буйлары белән әйләндереп алынган табигатьнең гүзәл почмагында урнашкан. Аның барлыкка килү тарихы даКазан ханлыгының чәчәк аткан чорына туры килә. Иске Мәңгәр авылына да шул вакытта нигез салына. Ә Олы Мәнгәр, Яңа Мәнгәр авылларының чишмә башы булып, авылым тора. Әлбәттә, авылымда эшчән, тырыш халык яши. Җыеп әйткәндә, безнең авыл халкы гомер-гомергә эшчән халык булган. Ирләр дә, хатын-кызлар да күп төрле һөнәрләр белгәннәр. Үз һөнәрләренә кечкенәдән үк балаларын да өйрәткәннәр. Һөнәргә ир балаларны – ата кеше, кыз балаларны – ана кеше өйрәткән. “Егет кешегә җитмеш төрле һөнәр дә аз,” – дигәннәр борынгылар. Моның белән алар һәр һөнәрнең кирәклеген, тормышта һәрвакыт ярап куярга мөмкинлеген искәрткәннәр.Әбиләребез чигү чиккәннәр: сөлгеләр, ашъяулыкларга, пәрдәләргә, киемнәргә төсле җепләр белән матур бизәкләр төшергәннәр. Сәйлән белән калфак, түбәтәйләр чиккәннәр. Аучы бабаларыбыз чын мәргәннәр булганнар. Аучылар- Ибраһимов Газиз, Нуриев Гаделшә, Нурмөхәммәтов Ихсан. Аларның Каенсар урманын кызыл флажоклар белән әйләндереп җиде бүре атканлыгы билгеле. Шул вакытта тагы ике бүреләре качкан. Алар:

-Их, әрәм иттек, качырдык,-дип уфтанганнар.

Профессиональ дәрәҗәдә умартачылык белән шөгыльләнүчеләргә Садыйков Закир, Нурмөхәммәтов Ихсан, Нуриев Гаделшә, Ибраһимов Газиз, Сафиуллин Абдулла, Нуриев Нурмөхәммәт, Хафизов Гыйбадуллалар керә. Ә Җиһанша карт бик оста бакчачы була.Аның бакчасында кавын, карбыз кебек көньяк җимешләре үсүе мәгълүм. Әкем Зайдие кулюк үрә. Кулюк ул - юкә агачының кабыгыннан ясалган мунчаладан, төрле савытларны салып кую, әйберләр тотыру өчен үрелгән капчыклар.

Икенче Бөтендөнья сугышына тикле Гөлбичә аланлыгында текстиль цехы эшли.Анда җитен чүбегеннән (пачас) бияләйләр җитештерәләр. Бу цехны Юнусов Абдуллаҗан абзый җитәкли. Чимал өчен сүсләрне җитен, киндер үстереп хәзерлиләр. Пачас бияләйләр махсус килешүләр нигезендә хөкүмәткә тапшырыла. Бу бияләйләр - зинданда утыручылар өчен

махсус бәйләтелгән. Шулай ук авылдан бер километр ераклыкта,Тегермән суы буенда, сабын кайнату алачыгы була. Анда Вәлиәхмәтова Рәбига (Локман) сөяк кайнатып сабын ясый. Сыек сабын хөкүмәткә тапшырыла.Симет елгасының Каенсар урманы тирәләрен Тегермән суы дип атыйлар.Чөнки элек шул тирәләрдә өч су тегермәне эшләп торган. Тегермән суы дип аталуга да шул тегермәннәр сәбәпче була. Шулай ук халык телендә фарфор чыгару, анда Баһави атлы кеше эшләве, Пимбе тавындагы таш карьерлары, таш чыгаручы Мөхәммәтша хакында да сөйләнелә. Кызганыч, бу мәгълүматларны раслаучы документлар һәм белгән кешеләр бүгенге көндә калмаган инде.

**1.Оста куллы Әхмәтгали.**

Тырыш халкы белән билгеле авылда Әхмәтгали бабам белән Сәрвәр әбием гомер итә. Бабам Казаннан ат белән урыс күмере алып кайта торган булган.Ул күмерне хуҗабикәләр самавыр кайнату өчен кулланганнар. Аны эшләү өчен нарат агачы да, киселгән агачның тамырлары да файдаланыл- ган. Утын шакмакларыннан агач сагызын кайнату юлы белән алынганнар. Агач шакмаклар зур казанга салынган. Өсте әйбәтләп ябылган һәм төбенә якканнар.Утын шакмаклары кызган. Алардан сагыз аерылып чыгып, казан төбендә дегеткә әйләнгән. Шул сагызы алынган күмер- урыс күмере дип аталган. Ә дегетен арба көпчәкләре майларга тотканнар.

Шунысы кызыклы: бабамны Алтынчы Әхмәтгали дип йөрткәннәр.Ул кешеләргә сынган алтын алкаларын төзәтү, көмештән йөзекләр ясавы белән билгеле. Аңа мондый осталык каян килгәндер, анысы безгә билгесез. Казан ханлыгы чорында, авылыбызда хан казнасы, өчен көмеш тәңкәләр сукканнар. Бәлки, җеп очы шуна бәйледер...

**2.Нәселдән бирелүче һөнәр дәвамчысы**

1907 нче елда туган Габделнур исемле улы да сынатмый. Хәдичәбикә исемле кызга өйләнә. 1941 нче елда Икенче Бөтендөнья сугышына китә.1943 нче елда дошман снарядыннан аягы яралана. Камалышта калмас өчен, яралы килеш, елга кичә. Аңа елганың икенче ярындагы авыл халкы ярдәмгә килә. Совет сугышчылары авылга кергәнче яралы бабамны яшерергә булышалар. Ике-өч көннән авылга кергән үзебезнекеләр, бабама ярдәмгә киләләр. Габделнур бабамның авызына агач кашык каптырып, наркозсыз килеш ярасыннан снаряд кыйпылчыклары чүплиләр. Һәм бик әйбәтләп бәйләп, госпитальгә озаталар. Бабамның аягы тазара, ләкин сөяге дөрес ялганмый. Госпитальдәге врачның кире сындырып ялгыйк дигән тәкъдимен ул кире кага.Чөнки, әйткәнемчә, бу вакытта барлык процедуралар да наркоздан башка ясала. Коточкыч газапларны аның тагы кичерәсе килми.Шулай итеп ул 1943 елда комиссовать ителеп авылга кайта. Төрле эшләрдә эшли.Авылда чалгы таптаучы да була. Бу хезмәте өчен халык аңа йомыркалата түләгән. Ә 1951 нче елда амбар мөдире булып эшләгәне билгеле.Хәдичәбикә әбием белән 8 балага тормыш бирәләр. Ләкин бер уллары белән кызлары кечкенә вакытта авырып вафат булалар. Калган алты баласы да тормышта үз урыннарын табып яшиләр.Эштәге зур тырышлыклар да буыннан-буынга күчә килә. Әхмәтгали бабамның улы - Габделнур да әтисенең шөгылен үз итә. Әтисе кебек, сынган алка бөгәрҗәләрен төзәтә, көмештән кашлар куеп, йозекләр,алкалар ясый, тишелгән җиз комганнарны ябыштыра. Бу хезмәтне башкара торган кораллары да була.Эшкәртәсе материалдан төрле тапларны, майларны алу өчен цинк катыш кислотасы да, кургаш, пояльник, кечкенә сандал, тиски, 4-5 төрле чүкеч, төрле фигуралар бирүче махсус зубиллары, көмешне үлчи торган кечкенә үлчәве дә булган. Аның эш өстәле дә соңгы елларга кадәр сакланды. Ул башта көмеш акчаны, чулпыларны калай калынлыгына калдырып төя торган була. Кайчысы белән тиешле киңлектә кисә.Аннан махсус кораллары белән эшкәртергә тотына. Кашлы алкалар, йөзекләр сораганнарга, каш куя торган булган.Көмеш тәңкәләрне дә бабам икегә аерган.Аларның йомшак һәм каты төрләре булган. Йомшаклары белән бөгәрҗәләр бөккән. Ә көмеш калдыкларын бакыр стаканга салып барган.Ул:

-Бакыр- көмешне, көмеш- алтынны саклый,- дип әйтергә ярата торган була.Чөнки байлар үзләренен тәңкәләрен шушы ысул белән саклаганнар. Имән сандыклар

алганнар.Төпкә бакыр акчалар салып калдырганнар, аның өстенә көмеш тәңкәләр салынган, көмеш өстенә алтыннарны тезгәннәр.

Менә шул бакыр стаканга салынган көмеш калдыкларын, бабам тимерчегә алып менеп, горнада эретә торган булган. Эрегән көмешне махсус өслеккә агызып суыткан. Эретелгән көмеш сыйфаты ягыннан калышкан. Аны эшләнмәнең четерекле җирләрен ясауда файдалана алмаган. Тагы Габделнур бабам, тотлыккан балалар өчен көмештән, балталы ачкычлар ясый торган була. Ырым буенча баланың муенына, бер кат җепкә, балталы көмеш ачкыч асып куелган. Йөри-йөри шул җеп өзелеп ачкыч төшеп калгач, баланың тотлыгуы да бетәргә тиеш булган. Ләкин бу ырымның кешегә тәэсир итеше безгә билгесез.

Алар әбием белән бәхетле гомер кичерәләр.1983 нче елда 76 яшендә бабам вафат була. Аннан соң да озак еллар әбием, авылыбызның абыстае булып, халыкка хезмәт итә.

Шундый оста куллы булган да инде минем бабам. Ул бүгенге көндә дә халык телендә Алтынчы Габделнур исеме белән телгә алына.

**3.Бүгенге көн дәвамчылары**

Бүгенге көндә бабамның нигезендә оныгы Илнур җәмәгате белән гомер итә. Бабамның осталыгы Илнур абыем белән әтиемә дә күчкән дип саныйм. Алтын, көмештән йөзек, алкалар ясамасалар да, тимердән төрле эшләнмәләрне бик тиз коеп куялар. Аларның үз куллары белән җыйган тракторлары, төрле эшләнмәләре шуны дәлилли. Абыем Илнурның да ике улы әтисенең хоббиена тартылалар. Һәр эштә ярдәм итәләр. Абыем да гел әтием тирәсендә бөтерелергә ярата. 8 нче сыйныфта гына укыса да, техника белән җенләнгән. Дүрт яшьлек энем Раяз да аның тирәсендә сырпалана.

**III.Йомгаклау**

Язмамны төгәлләп шуны әйтәсем килә:

-Алтынчы Әхмәтгалинең эшен дәвам итүче- Алтынчы Габделнур булды. Габделнур бабамның эшен дәвам итүчеләр булып – Илнур абый белән әтием тора. Ә алар үз чиратында нәсел эше өзелмәслек уллар үстерәләр.

Мин дә аларның хезмәт нәтиҗәләрен күреп куанам. Алар юлыннан ныклы адымнар белән бару өчен тырышып укыйм, хезмәт дәресләрендә күп төрле һөнәрләргә өйрәнәм.Чөнки “Белгән һөнәр иңсәне басмый” дип әйтергә яраткам бабам.

Буыннарыңны онытмас өчен, үзеңнең үткәнеңне белергә кирәк. Әгәр без борынгы бабаларыбызны онытсак, берникадәр вакыттан соң безне дә онытырлар.Кызыксыныйк, өйрәник, эзләник, белик! Белгәннәребезне киләчәк буыннарга тапшырыйк.Ә безнең бурычыбыз - ул еллардагы халыкның тырышлыгын, чыдамлыгын, батырлыгын үзебез дә онытмыйча, бездән соң килгән буыннарга да тапшыру.

**Кулланылган әдәбият**

1.Равил Фәйзуллин “Хәтерләүдән курыкма син! Үткәнеңне онытма син!” шигыре.

2.Мөхәммәтгалиевларның гаилә альбомыннан фотолар.

## ХЕЗМӘТ – ТОРМЫШНЫҢ НИГЕЗЕ

*Мухаметшин Руслан Рашит улы,*
*“Г.Х.Хабибрахманов исемендәге Олыяз урта мәктәбе”,*
*Кукмара районы*

**Тема: «Хезмәт – тормыш нигезе»** (5нче сыйныфта җәмгыять белеменнән дәрес конспекты)

**Дәрес тибы:** УКИЗ(урок комплексного использования знаний)
УЗЗВУ(урок закрепления знаний и выработки умений)

**Эчтәлеге:** хезмәтнең эчтәлеге һәм катлаулылыгы. Хезмәтнең нәтиҗәсе. Хезмәт хакы. Хезмәт – кеше тормышын җиңеләйтә.

**Аңлатмалар:** хезмәт, һөнәр, товарлар, хезмәтләр, хезмәт хакы.

**Көтелгән нәтиҗәләр** (ФГОС буенча):

- **Предметлы:** укучылар кеше тормышында хезмәтнең мөһим урын алып торуын характерлый алалар.

- **Метапредмет:**

**регулятив:** укучылар теманың төп проблемасын билгели алалар, шушы проблеманы чишүдә уку эшчәнлегеннән уңышлы файдаланалар.

коммуникатив: укучылар сораулар бирә алалар, дәрестә куелган проблеманы чишү барышында үзләренең шәхси фикерләрен җиткерә, иптәшләре белән диалог алып бара беләләр.

**танып-белү:**укучылар хезмәтнең кеше тормышы өчен никадәр мөһим булуын аңлатып бирә алалар, дөрес итеп хезмәтне мораль яки материаль бәяләнешен билгелиләр, кеше хезмәтенең нәтиҗәсендәниләр барлыкка килүен ачык итеп әйтеп бирә беләләр.

- **Шәхси:** укучылар төрле хезмәт нәтиҗәсендәсендәге уңышларга үз мөнәсәбәтләрен билгели алалар, киләчәктә һөнәр сайлауда …

Дәрес барышы:

1.Оештыру өлеше.

-Исәнмесез, укучылар! Утырыгыз. Бүгенге җәмгыять белеме дәресен башлыйбыз.

-Әйтегез әле, сез бүген дәрескә нәрсә эшләргә дип килдегез? (укырга, яңа белемнәр тупларга, сорауларга җаваплар табарга һ.б.)

-Рәхмәт, укучылар, җавапларыгыз өчен. Ә дәрес материалын ныклап аңлау өчен сез нәрсә эшләргә тиешсез? (укытучыны игътибар белән тыңларга, дәрестә актив катнашырга һ.б.)

-Әйе, мин дә сезнең кебек үк тырышып эшләрбез дип ышанам. Сезнең төп эшегез нәрсә? (Уку)

-Тактага игътибар итегез әле (бер укучы укый)

**Тактада «Эшле кеше – көчле кеше» мәкале язылган.**

-Димәк, укучылар, безнең эшебез бар. Моннан нинди нәтиҗә ясый алабыз: без көчле кешеләр.

2. Дәрескә кереш. Дәреснең максат һәм бурычларын билгеләү.

-Укучылар, ә хәзер сезнең белән татар мультфильмыннан кыска гына өзек карап үтәрбез. Игътибар белән карагыз, соңыннан кайсы бөек шагыйребезнең шигыренә нигезләнеп эшләнгән мультфильм икәнлеген әйтербез.

Слайд№ 1. «Эш беткәч уйнарга ярый» мультфильмыннан өзек карау (3 минут).

Мультфильмны карап бетергәннән соң авторын билгеләү (Г.Тукай).

-Укучылар, ни өчен дәресебезне нәкъ менә әлеге мультфильмны караудан башладык дип уйлыйсыз? Өзектә сүз нәрсә турында бара (эш, хезмәт).

Слайд№ 2.

-Нәрсә күрәсез, укып күрсәтегез әле? Аңлашыламы? Сүзләрнең язылышында нинди хата җибәрелгән дип уйлыйсыз? Хәзер адашкан хәрефләрне үз урыннарына куеп карагыз әле. Бик җиңел генә эшләп куела торган ысулы бар (укытучы аңлата). ***Дәрес темасының исеме чыга.***

-Димәк, бүгенге дәресебезнең темасы нинди булачак. (бер укучы әйтә :Хезмәт-тормыш нигезе). Узган дәрестә шушы тема буенча сөйләшә башлаган идек, әйдәгез, шуларны искә төшереп үтик әле. Нәрсәләр турында сөйләштек икән (укучыларның җаваплары)

2 хезмәт төрен ачыкладык:матди эшләр һәм хезмәт күрсәтү.

*Шулай ук сез өйдә төркемнәргә бүленеп хезмәт һәм эш сүзләре кергән мәкальләр язып килергә тиеш идегез. (Төркемнәр үз эшләрен яклый)*

***Төркемнәрдә эш (проект төзү хезмәт темасына)****: таблица бирелә бу таблицада аңлатмалар язылган ,шулай ук таблицага өстәмә материал бирелә һәм материал арасыннан аңлатмага туры килә торганын табып, А3 битенә ябыштырып куясы. Соңыннан һәр төркемнән 1 укучы проектларны яклый.*

3 укучы тактада эшли, калган укучылар дәфтәрләрне алыштырып иптәшләренең өй эшләрен тикшерәләр ( + - куялар).

4. **Яңа тема өстендә эш.**

**-Теманы өйрәнүне дәвам итәбез.** Китабыгызның 77 нче битенә тиз генә күз төшереп алыгыз әле. Без бүген дәрестә нәрсәләр турында сөйләшергә тиеш булабыз икән?

**Димәк,** -Хезмәт ничек бәяләнергә тиеш?

- Байлык һәм ярлылык

-Байлык таләп итә

-Рәсем

-Нинди кешене бай кеше диләр? (Байлык туплау өчен бик күп тырышырга кирәк)

**-Димәк,** материаль яктан гына бай һәм ярлыга аеру дөресме? Бирелгән сорауны ничек исбатлый алыр идегез? (Китапханә – кешене рухи яктан баетучы)

**Нәтиҗә ясап,кечкенә генә иҗади эш** (укучылар билге куялар: хатасыз-5, бер хата – 4, ике хата – 3)

Слайд№ 3. (Слайдта Әсхат Галимҗанов фотосурәте)

-Укучылар, бу кешене танышсызмы? Мәктәбебез директоры Гомәр Хашимович әлеге шәхес турында бик еш сөйли. (укучыларның җаваплары)

-Әйе, бик дөрес. Әсхат Галимҗанов һәрвакытта «Акча аяк астында, аны бары тик иелеп алырга гына кирәк», - дигән. Димәк, нәтиҗә ясап ни әйтә аласыз?

Укучы: Чынлап та, эшле кеше ул көчле кеше дип уйлыйм, чөнки эш булгач яшар өчен кирәкле әйберләрне сатып алып булла, эшләгән өчен акча түләнә. Безнең әти-әниләр төрле өлкәләрдә эшлиләр. Минем әти дә, әнидә укытучылар. Мин аларның хезмәте турында презентация әзерләп килгән идем. ( Назмиева Гөлия презентациясен яклый).

-Ә хәзер, укучылар, шушы ике дәрестә (теманы сорау) алган белемнәрне ныгытып кую максатыннан түбәндәге биремне эшләп алыйк (билге куялар).

Бу темага кагылган төп аңлатмалар.

**Өй эше.** Әсхат Галимҗановның тормыш юлы турында мәгълүмат туплау; сорауларга җавап әзерләү; хезмәт турындагы мәкальләрнең эчтәлеген аңлату. (укучылар 3 эшнең берсен сайлап алырга тиешләр).

**4. Рефлексия.**

-Укучылар, дәрес сезгә кайсы яклары белән ошады яки ошамады, үзегез нинди үзгәрешләр кертер идегез?

-Һәрбер төркем иң актив укучының исемен атап, аны сәламли.

-Бүгенге дәрестә алган белемнәрегез алдагы тормышыгызда кирәк булыр дип уйлыйсызмы?

-Дәресне нинди мәкаль әйтеп башладык? (Эшле кеше – көчле кеше)

Шушы сорауларга җавапны үсеш баскычында магнитлар ярдәмендә аңлатыгыз.

**Билгеләр кую.**

# ЭВАКОГОСПИТАЛЬ №2786 В КУКМОРЕ

*Набиева Нурия Миннахметовна,*
*МБОУ «Многопрофильный лицей*
*им. А.М. Булатова п.г.т. Кукмор»*

Предмет: краеведение
Класс: 10
Тип урока: исследование
Вид: урок с элементами самостоятельной работы учащихся
**Тема урока.** Эвакогоспиталь № 2786 в Кукморе.
**Цели**

Изучение истории родного края в годы Великой Отечественной войны через самостоятельную, парную, коллективную работу.

Совершенствование умений учащихся сравнивать, обобщать понятия и факты, работать в парах.

Формирование УУД: регулятивные, коммуникативные, познавательные.

**Планируемые результаты**

*Предметные*: знать смысл понятий и терминов: госпиталь, эвакогоспиталь, передислокация, Наркомздрав СССР.

*Знать основные события:* Великая Отечественная война 1941-1945 гг, перестройка на военный лад.

Уметь самостоятельно извлекать информацию; осмысливать теоретический материал;

*Личностные*: воспитывать уважение к историческому наследию России; развивать сотрудничество при работе в парах; доказывать свою точку зрения; выступать публично; формировать умение применять исторический материал для осмысления современных событий

***Метапредметные:***

*-регулятивные УУД:* формировать навыки планирования ответа; развивать навыки критического мышления; умения анализировать и обобщать

*-коммуникативные УУД*: развивать умение групповой и парной работы; умение формулировать и доказывать свою точку зрения, уважать противоположное мнение

*Познавательные УУД:* находить необходимую информацию, используя материал учебника; получать как можно больше информации, работая с легендой исторической карты

**Основные понятия** госпиталь, эвакогоспиталь, передислокация, Наркомздрав СССР.

**Межпредметные связи**: география, обществознание, право, литература.

**Отношения, ценности, внутренние установки:** выразить свое отношение к роли истории в жизни человеческого общества.

**Ресурсы: основные**, **дополнительные**: мультимедийная установка, методическая разработка, презентация мероприятия, учебник, рабочая тетрадь, архивные документы.

**Организация пространства** самостоятельная, парная, коллективная работа

**Форма урока:** изучение нового материала

**Вид:** урок с элементами самостоятельной работы учащихся

**Принципы работы:** систематичность, наглядность, дифференциация, индивидуализация.

**Ход урока.**

**I. Организационный момент.**

Приветствие.

**II. Мотивационно – целевой этап**

22 июня 1941 года около 4 часов утра, когда мирные советские граждане ещё спокойно спали, фашистская Германия без предъявления каких-либо претензий вероломно напала на Советский Союз. Почти на всем протяжении западной

государственной границы СССР стали рваться тысячи бомб и снарядов, предутренняя тишина огласилась рёвом немецких самолётов и гулом моторов танков. В 12 часов по радио заместителем председателя Совнаркома, наркомом иностранных дел В.М. Молотовым было оглашено правительственное сообщение о внезапном нападении фашистской Германии на СССР. «Это неслыханное нападение на нашу страну является беспримерным в истории народов вероломством. Нападение на нашу страну произведено, не смотря на то, что между СССР и Германией заключён договор о ненападении и Советское правительство со всей добросовестностью выполняло все условия договора». Сообщение заканчивалось словами: «Наше дело правое, враг будет разбит, победа будет за нами!» эти знамениты е слова стали боевым девизом для миллионов граждан многонационального Советского государства.

**Тема урока:** Эвакогоспиталь № 2786 в Кукморе.

**План урока.**

1. Эвакогоспитали в Татарской АССР
2. Эвакогоспиталь № 2786
3. Повседневная жизнь эвакогоспиталя № 2786

Великая Отечественная война 1941-1945 гг. навсегда останется в памяти как беспримерный ратный и трудовой подвиг нашего народа. Территория Кукморской области не подвергалась оккупации. Здесь не гремела канонада, не горели города и села. Её земля не была изрыта окопами, обезображена воронками от снарядов, мин и бомб. Но это совершенно не означает, что пламя войны обошло её стороной. Мы помним о погибших. Не зря сегодня и всегда у братской могилы на русском кладбище цветы, приношения людей. А госпиталь – это горькая и тяжелая страница в истории нашей школы.

Так, жизнь небольшого поселка Кукмор и близ лежащих деревень, которые входили накануне и в годы ВОВ в Кукморский район, с началом войны резко изменилась. Всё: и колхозы, и школы, и больницы - стало перестраиваться на военный лад. Люди жили и работали под лозунгом «Все для фронта, все для победы!», фронт и тыл были едины против врага.

**III. Работа по теме урока.**

**1. Эвакогоспитали в Татарской АССР**

Под эвакогоспитали в Татарской АССР в июне - июле 1941 года было передано 70 зданий клиник, школ, техникумов, учебные корпуса некоторых вузов, дворцы культуры, санатории и дома отдыха. Уже на десятый день войны в Казань и другие города республики стали поступать раненые. К началу декабря 41-го года было принято более 37 тысяч раненых и больных бойцов. В этот период действовали 50 госпиталей, в том числе 42 - в Казани.

- *У вас на столах лежат четыре документа. Вы должны проанализировать эти документы. При ответе опирайтесь на план анализа исторического документа. (Приложение 1)*

2. **Эвакогоспиталь № 2786**

Население помогало постельными принадлежностями, мебелью, теплой одеждой для раненых. Начальником госпиталя и главным врачом был военный врач 2 ранга Лаптев Николай Ананьевич, комиссаром был Славов (имя и отчество не установлены), позднее комиссаром госпиталя стал Садыков Гали Галиевич. Из письма Гали Галиевича стало известно, что эвакогоспиталь № 2786 имел 4-е отделения: КСШ №1, КСШ №2, сад-ясли (ул. Вахитова) и больница. Контора госпиталя находилась внизу госбанка (там, где сейчас находится районный музей).

- *А теперь работаем с документом № 5. Какие были выделены проблемы были выявлены исполкомом? (Приложение 2)*

**3. Повседневная жизнь эвакогоспиталя № 2786**

21 августа 1941 года из Казани в Кукмор переезжает 2786 эвакуационный госпиталь. Который буквально с первых дней начинает принимать первых пострадавших. Народ Кукмора очень доброжелательно встречает раненных бойцов. Медицинские работники не жалея сил делают всё, чтобы залечить раны, поставить на ноги людей. Вот что пишут дети.

«1 сентября 1941 года, мы одиннадцатилетние мальчишки и девчонки пришли в школу. Но не на занятия. В школе № 2 расположился военный госпиталь. Принимали с эшелонов раненых солдат. Медсестры были для бойцов, как матери, как сестры, как медики, а мы, дети, стирали бинты, писали письма их родным и близким, читали стихи, пели песни – старались отдать раненным тепло души, облегчить страдания. Для нас в те дни не было больших и малых дел. Каждое дело было главным и важным».

*- Предлагаю вам поработать разбившись на группы. Каждая группа получит дополнительный материал – письмо раненного бойца и внимательно его изучит. Ответить на вопросы:*

1. *Нарисуйте возникшую в вашем воображении картину происходящих событий.*
2. *Попробуйте описать личность автора письма, определить черты характера, рассказать о его семье.*

***Задание для первой группы:***

Эти письма Деминкова Ивана Григорьевича, жителя г. Гагарина Смоленской области. Он освобождал от фашистов Тихвин, Волхов, Харьков, Польшу. Форсировал Вислу, Одер, дошел до Берлина. В боях получил 5 ранений. После одного ранения лечился в военном госпитале в Кукморе. Бывший воин навсегда запомнил внимательное отношение кукморян. Вот что он пишет:

*«В конце июня 1942 года около 200 тяжелораненых приехали из Казани в Кукмор. Многие были прикованы к койке. Большинство из нас даже при помощи костылей не могли передвигаться. Но и не только нам, тяжелораненым, но и тем, кто мог передвигаться, встречающие пройти и метра не давали без людской помощи. Нас встречал не только персонал госпиталя, но и жители поселка. Лично меня несли на носилках 4 девушки – татарки, а костыли – ребятишки. Это была действительно материнская встреча - любовь к нам, фронтовикам, со стороны всех встречающих».*

***Задание для второй группы:***

**Белов Юрий Леонидович, сержант, танкист.** *Из писем родителям, август 1941.*

*«Здравствуйте, мои родные! Я нахожусь сейчас в госпитале. 29 числа под деревней Роги проклятый немец саданул в ногу. Пуля еще там. Сегодня хотели вынимать. Прошу обо мне не беспокоится. Настроение отличное. Вот обидно, что ранен в такой момент, когда на фронте наступает переломный момент...*

*...Мои родные, война показала, что мое влечение в морское училище было очень и очень глубокое. Война, несмотря на лишения и жестокости, - моя стихия. Там я чувствую себя, как рыба в воде. Я, не хвастаясь, могу сказать, что из меня выйдет хороший военный специалист, но только не пехотный. Это дело мне не очень нравится, но и в пехоте ничего. И в пехотном бою чувствую себя превосходно, но попросту этот род не нравится. С какой завистью я читаю сводки морского флота…»*

***Задание для третьей группы:***

Без даты:

*«Здравствуйте, дорогие мои жена Нинок, доченька Ниночка и милая мамочка! Шлю вам сердечный привет, а также горячо целую любимую мою жену, дочь и мамочку.*

*Милая Нинок! Живу хорошо. Чувствую себя прекрасно, скоро, может быть, смогу ходить, тогда буду просить выписать снова на фронт и за все отомстить проклятым фашистам.*

*Как много прошло времени, что мы не виделись, не слышали разговора, не имели возможности крепко, хорошо любить.*

*Вот сейчас лежу на кровати, часто вспоминаю тебя, мою крошку, миленькую доченьку, как вы приходили ко мне в госпиталь в прошлом году. Ведь тогда было очень весело и лечиться, зная, что рядом находится любимая жена, которая тоже заботиться о моем здоровье.*

*В настоящее время мне много труднее быть на родине, где нет никого, кто бы навестил в тяжелую минуту.*

*Милая жена! Скоро наступит тот день, когда встретимся, крепко обнимем и поцелуем друг друга. Будем строить нашу счастливую жизнь. Воспитаем нашу доченьку умной, веселой девочкой и под старость будем ею любоваться.*

*Прошу тебя, моя любимая, все силы приложи, но сохрани ее. Если приду, то ты будешь отдыхать и ни на какую работу не пойдешь, так как жила до войны.*

*Крепко целую любимую жену, миленькую доченьку, мамочку, Люсю Гарьку. Привет Фисы и ее детям. До свидания. Твой муж Анатолий»*

***Задание для четвертой группы:***

*«Здравствуйте, мамаша, братишка Ваня, сестренки Анфиса и Верочка!*

*Я жив, здоров, чего и вам желаю. Я был ранен в правую ногу осколком. Награжден медалью "За отвагу". И скоро вновь вступаю в бой. Должен получить орден Красного Знамени. Если умру за Родину, то буду орденоносцем. На днях около меня взорвалась мина, убила моих товарищей, а я остался жив. Живу хорошо, всего у меня достаточно. Мы гоним немцев так, что они бегут и все бросают. Я одного немца захватил в окопе, замотал в одеяло и привез к своим. Пишите чаще.*

*Ваш сын М. Власов».*

***Задание для пятой группы:***

*«Здравствуй, моя дорогая Паля и мои дети Галя и Шура.*

*Шлю я вам свой сердечный привет и желаю быть здоровым. Паля, я пока жив и здоров, сейчас, пока нахожусь в госпитале, только в другом, нас из того госпиталя эвакуировали. Паля, я тебе посылал письмо 1-го июня, от вас нет никакого ответа. Телеграмму я вашу получил, которую вы посылали в мае месяце. Но письмо я сюда, получил только одно. Паля, спеши послать письмо. Пиши, как вы живете. Я буду ждать. У меня здоровье пока ничего, недавно была операция, рука стала заживать. Заживет рука, снова поедем добивать немцев, которые еще остались живы. Паля, передавай привет моей бабушке Парасковье и моим братьям. От моего братишки, наверно, нет никакого ответа. Пока, до свидания.»*

Госпиталь работал до декабря 1942 года. За это время, как это не прискорбно, часть раненных всё же погибла и их похоронили в Кукморе. *(Приложение 3)*

Долгие годы хранили в своей памяти заботу этих тружеников госпиталя и те, кто лечился здесь. Память о Великой Отечественной войне кукморцы хранят свято. Эту благородную миссию, прежде всего, выполняют школьные музеи. В каждом из них есть экспонаты, рассказывающие о земляках – участниках войны и тыла. Продолжается скрупулезная работа по выявлению новых имен пропавших без вести. Помните, знаменитое выражение: «Пока не похоронен последний солдат, война не окончена…»

**IV. Итоги урока. Рефлексия.**

"Благодарю…".

В конце урока учитель предлагает каждому ученику выбрать только одного из ребят, кому хочется сказать спасибо за сотрудничество и пояснить, в чем именно это сотрудничество проявилось. Учителя из числа выбираемых следует исключить. Благодарственное слово педагога является завершающим. При этом он выбирает тех, кому досталось наименьшее количество комплиментов, стараясь найти убедительные слова признательности и этому участнику событий.

**Домашнее задание.**

1. Кого из героев Советского Союза уроженцев, Кукморского района вы знаете? Подготовьте сообщение «Герои Советского Союза – мои земляки».

2. Найдите в книге «Память» своих земляков погибших на фронтах второй мировой войны.

## НИНДИ МӘЙДАН ЗУРРАК?

*Нәбиева Зөлфия Мөхәмәтзөфәр кызы,*
*Сәрдекбаш урта мәктәбе,*
*Кукмара районы*

**3 нче сыйныфта математика дәресе**

**Дәрес тибы:** яңа белемнәр ачу

**Максат:** фигураның «мәйданы» төшенчәсе белән таныштыру, фигураларның мәйданнарын чагыштыра белү.

Төп компетенцияләр формалаштыру: танып белү, информацион, коммуникатив, үстерешле.

Дәреснең бурычлары:

Белем бирүче: фигураларның мәйданнарын чагыштыру юлларын өйрәнү, фигураларның мәйданнарын чагыштыра белү.

Геометрик фигураларның билгеләре һәм үзлекләре турында белемнәрне актуальләштерү.

Исәпләү күнекмәләрен камилләштерү.

Үстерешле: төп фикерләү операцияләре үсешенә булышлык итү(чагыштыру, йомгаклау, алынган информация нигезендә нәтиҗә ясау).

Проблеманы анализлау һәм чишү юлларын табу осталыкларын үстерү.

Төп УУГ (уку мәсьәләсе куя белү, чагыштыру, йомгаклау, алынган информация нигезендә нәтиҗә ясау) компонентлары формалаштыру.

Тәрбияви: Үзанализ күнекмәләре формалаштыру.

Пөхтәлек, мөстәкыйльлек,үзара ярдәмләшү һәм дуслык хисләре, игътибарлылык , группада, парларда, коллективта эшли белү, иптәшеңнең җавабын игътибар белән тыңлый белү осталыклары тәрбияләү.

УУГ формалаштыру:

Планлаштырылган нәтиҗәләр:

Шәхси: уку эшчәнлегеңне критерийлар нигезендә бәяли белү, математик белемнең тормышта кирәклеген аңлау.

Метапредмет:

Регулятив УУГ: дәресне максатын билгели һәм әйтә белү, үз фикереңне билгели белү,коллектив төзегән план нигезендә эшли һәм гамәлләреңнең дөреслеген бәяли белү, уку мәсьәләсе нигезендә үз эшчәнлегеңне планлаштыра, төзәтмәләр кертә белү.

Коммуникатив УУГ: фикерләреңне телдән математик телдә әйтү, иптәшләреңнең сөйләмен тыңлау һәм аңлау, группада эшли белү, үз фикереңне формалаштыра һәм яклый белү.

Танып-белү УУГ: үзеңнең белем системасында ориентлашу: яңаны белгәннән аеру, тормышта куллану; сорауларга җавап табып, дәреслекне кулланып, үзеңнең тормыш тәҗрибәңә, дәрестә төрле чыганаклардан алынган информациягә таянып яңа белемнәргә ия булу.

Предмет:

“Мәйдан” төшенчәсен аңлау, шул нигездә төрле фигураларның мәйданнарын чагыштыра белү, тормышта кирәклегенә төшенү һәм шуны исбатлау.

Системалы эшчәнлек технологиясе.

Укучылар белән эш формалары: фронталь, парлы, индивидуаль, группада

Җиһазлау: презентация, ноутбук, геометрик материаллар, һәр укучыга 3 төрле смайлик.
Чекин А. Л. Математика. 3 нче сыйныфөчендәреслек.
УМК «Перспектив башлангыч мәктәп»

**Дәрес барышы:**

I.Уку эшчәнлегенә мотивация.

Укытучы:
-Дәрестә безнең күзләребез күрә,
Колакларыбыз ишетә,
Кулларыбыз яза,
Башыбыз ... .(Укучылыр җавабы: уйлый, эшли һ.б.)

1).Дежур укучы: бүгенге число, атнаның көне, класста ... градус җылы.

Дәфтәргә число, сыйныф эше, матур язу: 7 77 777 7777 …

Саннарны укыту. НАМБЭ АП структурасы нигезендә 7нең х таблицасын кабатлау.

2) Слайд 1.СИ-ФИНК-УАНДЭ фикерләү алымы:
1.Син нәрсә күрәсең?
2.Син бу турыда нәрсә уйлыйсың?
3.Синең нәрсә турында беләсең килә?

Дәрестә игътибарлы булырга кирәк дигән нәтиҗә ясала: иптәшеңә карата: аны игътибар белән тыңлыйсы, аңа булышасы; үзеңә карата: син моны белә идеңме, бу сиңа кирәкме, кайда кирәге чыгачак; укытучыга карата: ул булышып, юнәлеш биреп тора.

II.Белемнәрне актуальләштерү һәм сынау максаты белән уку гамәле.

1).Слайд 2. Мисалларны чишәргә, килеп чыккан сүзне укырга.

1)345х1 3)130:5 5)90423:90423
2)0х987 4) 96 :6 6) 9876: (764-763)

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 26 | 9876 | 345 | 16 | 0 | 1 |
| й | н | м | д | ә | а |

-Нинди сүз килеп чыкты? (Мәйдан)
-Сез бу сүз белән танышмы?
-Дәреснең темасы нәрсә дип уйлыйсыз? –Мәйдан.
- Бу сүзнең мәгънәсен ничек белергә була?(Аңлатмалы сүзлектән, интернеттан карап, сорап).

Слайд 3. Мәйдан-ул фигураның яссылыкта алган урыны. Русча-площадь.
1.Шәһәрдә, авылда төзелеш булмаган зур ачык тигез җир,урын. Аннан төрле якка юллар китә.
2. Нинди дә булса бина, торак йорт.
3.Яссылыкның сызык белән әйләндереп алынган өлеше, фигураның мәйданы.

Үзбәяләү.

III.Кыенлык тудыру.

СОРТ КАРДС фикерләү алымы ПЛЕЙСМЭТ КОНСЕНСУС структурасы (уртак фикер уртага языла)

Сезнең каршыгызда фигуралар (төрле зурлыктагы һәм төрле төстәге өчпочмаклар, квадратлар, түгәрәкләр, турыпочмаклыклар).Аларны ничә төрле юл белән 2 группага бүләргә була?

Укучылар ТАЙМ РАУНД РОБИН структурасы буенча җавап бирә:
1. Зур һәм кечкенә
2. Почмаклыклар һәм түгәрәкләр.
3. Төсләре буенча.

-Без зур һәм кечкенә фигуралар белән эшләрбез.
-Фигураларның зур һәм кечкенә икәнен ничек белдегез? (күз белән чамалап)
- 2 квадратны чагыштырыгыз: кайсы зуррак? Күз белән чамалап буламы?(берсе өстенә берсен куеп карыйбыз, тәңгәл килсәләр, тигез булалар, кечкенәсен зурысы өстенә куябыз).

-Мондый очракта квадратның мәйданы өчпочмак мәйданыннан зуррак, өчпочмакның мәйданы квадрат мәйданыннан кечкенәрәк диләр.

- Квадрат белән турыпочмаклыкны чагыштырыгыз? Күз белән чамалап буламы? Берсе өстенә икенчесен куеп карагыз?

-Ничек чагыштырып була дип уйлыйсыз? Бу проблеманы ничек хәл итәрбез?

IV.Кыенлыктан чыгу алгоритмын төзү:

Эзләнүле эшчәнлек: дәреслекнең 52 нче бите № 145 нең сызымы.

-Нишләргә була? –Тигез квадратларга бүләргә була.

-Фигураларыгызны әйләндереп карагыз әле, тигез квадратларга гына бүлеп буламы? Тагы ничек бүләргә була? ( бертөрле өчпочмакларга, турыпочмаклыкларга)

ФИНК РАЙТ РАУНД РОБИН (уйла-яз-командада тикшер)

Слайд 4. Фигураларның мәйданнарын чагыштыру өчен:

1.Аларны бертөрле квадратларга (өчпочмакларга) бүләбез.

2.Кайсы фигурада кечкенә квадрат саны күбрәк, аның мәйданы зуррак була.

3.Квадрат саны әзрәк фигураның мәйданы кечкенәрәк була.

Физкультминутка

V.Төзегән алгоритмны тормышка ашыру. №146, 53 бит.

VI. Укучыларның эчтән әйтеп беренчел ныгыту этабы. №143, 52 бит.

Мәйдан турында нәрсә белдегез? ( Мәйдан- буялган идән, эш)

VII. Мөстәкыйль эш. №145, 53 бит, №148,54 бит.

Слайд 5. Эталон буенча дөреслеген тикшерү.

Үзбәяләү.

VIII. Белемнәр системасына кертү һәм кабатлау.

Слайд 6.ТОКИН МЭТ структурасы: мәйдан нәрсә ул? Класс мисалында язасы.Нәрсәләрнең мәйданнарын чагыштырырга була: зур, кечкенә, тигез?

Тәрәзә мәйданы- аны чистарталар, рамын буйыйлар.

Стена мәйданы- аны агарталар.

Такта- аны сөртәләр.Идән-юалар, лаклыйлар, такта, линолеум, палас җәяләр һ.б.

Укучылар аерым биткә яза,тактага элеп куя.

Иптәшеңнең эшен бәяләү һәм үзбәяләү.

XI.Рефлексия.

-Дәрестә нәрсәләр белдегез?

Слайд 6 :

-Мин ...белдем.

-Миңа ошады...

-... авыр булды.

...кирәк булачак.

- Өй эше:Дәфтәр 38 бит.

Иҗади эш:өйдә мәйдан чагыштыруга 3 мисал табарга.

## “ТУГАН ЯКНЫ ӨЙРӘНҮ ” БУЕНЧА ДӘРЕСТӘН ТЫШ ЭШЧӘНЛЕК ПРОГРАММАСЫ

*Нәбиева Рәмзия Мәүлит кызы,*
*“Ядегәр авылы Г.Г. Гарифуллин исемендәге*
*урта гомуми белем бирү мәктәбе” нең*
*биология укытучысы*

Аңлатма язуы

Җәмгыятебез тамырдан борылыш чорын кичерә. Мәктәпнең уку-укыту системасына нинди генә үзгәрешләр кертелсә дә, хәзергә рухи-әхлакый тәрбия бирүдә тиешле нәтиҗәгә

ирешелми әле. Яшь буынның бүген алган тәрбиясе халкыбызның алдагы көнен билгели. Яшь буынга әхлак, патриотик һәм рухи тәрбия бирүдә нинди үтемле чаралар кулланырга соң? Милли мәктәпнең укыту-тәрбия эшчәнлегендә музейлардагы хәзинәне: тарихи экспонатларны, халкыбызның рухи һәм матди культурасын, бүгенгесен һәм узганын чагылдыручы материалларны, музей педагогикасын куллану – әлеге мәсьәләне хәл итүдә мөһим чараларның берсе.

Туган ил. Туган авыл. Туган җир. Бу изге сүзләр һәркемгә таныш һәм кадерле.

Ватанпәрвәрлек дигәндә, без балаларны милли үзаңга һәм гражданлык хисенә ия булган шәхесләр, Ватанның лаеклы уллары, кызлары итеп тәрбияләүне күз алдында тотабыз. Ватанпәрвәрлек – үз иленә, туган җиренә, халкына, табигатькә, милли традицияләргә, мәдәниятка мәхәббәт ул.

Әлеге проект бүгенге көндә бик **актуаль**, чөнки үз тарихын белмәгән халыкның киләчәге юк. Моның өчен һәр бала үз гаиләсенең, туган җиренең тарихын белергә, шуның аша халыкка якынаерга тиеш. Шәҗәрәне өйрәнү нәсел-ыру традицияләрен, гореф-гадәтләрен, йолаларын, әдәп-әхлагын, шөгель-кәсепләрен белү һәм дәвам иттерү өчен кирәк. Шулай булганда гына яшь кеше милләт җанлы, үз халкының улы булып җитлегә ала, анда милли аң ышанычлы формалаша.

Проектның төп **максатлары**:

- Укучыларда республика, район, авыл тарихы турында күзаллау булдыру;
- Балаларны милли мәдәният белән таныштыру;
- Рухи-әхлакый сафлыкка ия булган иҗади шәхес тәрбияләү.

Туган җиребезнең тарихын һәм гореф-гадәтләрен өйрәнеп, әхлаклы, милли аңлы шәхес тәрбияләүгә ирешү проектның **гипотезасы** булып тора.

Проектны тормышка ашыру укучыларда (интеллектуаль, иҗади һәм гамәли) **белем** һәм **күнекмәләр** булдырырга мөмкинлек бирә.

Алар:

- Туган якны, кече Ватаныбызны өйрәнүгә кызыксынуны арттыруда;
- Туган якны өйрәнү өчен кирәк булган белемнәрне аерып ала белүдә;
- Кешелекнең тарих белән үзара тәэсир итешүен бәяләүдә;
- Тикшеренү өчен практик һәм теоретик күнекмәләр белән эш итә белүдә күренәләр.

Гипотезаны тикшерү һәм максатка ирешү өчен түбәндәге **бурычларны** чишергә кирәк:

- Танып белү күнекмәләрен, кызыксынуларын үстерү;
- Үз халкына, тарихына, гореф – гадәтләренә, мәдәниятенә карата кызыксыну уяту, үз милләте тарихына, яшәешенә битараф булмаска өйрәтү;
- Үз халкы белән горурлану хисе тәрбияләү;
- Милләтебезнең гасырлар буена тупланган әдәп-әхлак нормаларын булдыру;
- Иҗат итү омтылышы уяту;
- Тарихи шәһәрләргә, табигатькә экскурсияләр үткәрү.

Куелган бурычларны чишү өчен үзара тулыландыругы **методлар** комплексы кулланылды:

- Теоретик (фәлсәфи, фәнни, методик әдәбиятны анализлау;)
- Эмперик (әңгәмәләр, төрле темаларга сораштырулар, алдынгы тәҗрибәләрне гомумиләштерү)

**Проектның төре**: гамәли-юнәлдерелгән. Проект катнашучыларның социаль кызыксынуларын канәгатьләндерүгә юнәлдерелгән.

**Дәвамлылыгы** ягыннан озак вакытлы, чөнки үткәрү вакыты 4 елга исәпләнгән.

Проектның **функцияләре**: күп функцияле, гамәли, мәгълүмати,иҗади, тикшеренү.

Проектның катнашучылары 5-11 сыйныф укучылары.

Проект **5 бүлекне** үз эченә ала

**Проектның бүлекләре**

1. Әй, мәктәбем-белем учагы, син гомернең иң гүзәл чагы!
2. Нәсел тамырым тирән минем, ерак гасырлардан башлана.
3. Колхоз тарихы
4. “Туган җирем, үскән җирем, гади генә бер авыл”, Авылым - минем язмышым
5. Якташларыбыз Бөек Ватан сугышында

“Мәктәбебез тарихы” бүлегендә мәктәпнең бер гасырга якын тарихы, аның директорлары, укыткан укытучылары, чыгарылыш укучылары турында материаллар, альбомнар.Ветеран укытучыларның, элекке укучыларының истәлекләре, уку алдынгыларының, медалистларның фотографияләрен тупладык. Пионер тарихына караган экспонатлар - галстуклар, быргы, барабан, Ленин бабайның бюсты, значоклар, байраклар һәм укучы формаларын урнаштырдык.

“Колхоз тарихы”дип аталган бүлекбезнең горурлыгыбыз булган авылдашыбызга багышланды. Анда аның шәхси документлары, мактау кәгазьләре һәм бик күп фотокарточкалары урнаштырылды. Аларнын истәлекләре орден-медальләре безнең өчен бик кадерле экспонатлар. Колхоз тарихына караган альбомнар, авылыбызның хезмәт алдынгылары турында газета материаллары, күп санда фоторәсемнәр тупланды. Бу бүлектә колхоз елларында кулланган эш кораллары сука, сәнәк, көрәкләр, тәгәрмәч, калыплар, кул тегермәне һәм башкаларны экспонатларны күрергә мөмкин.

“Якташларыбыз Бөек Ватан сугышында” дип аталган бүлектә ветераннарыбыз турында мәгълүматлар,тыл ветераннарына багышланган альбомнар, ”Хәтер китабы”, совет солдаты котелогы, фляжкасы, солдат калагы,солдат хатлары, фотокарточкалар урнаштырылды.Шулай ук орден-медальләр, аларның документлары, грамота, мактау кәгазьләре һәм хәрби документлар тупланды. Бу материаллар укучыларга патриотик тәрбия бирүдә зур таяныч булып тора.

“Авыл тарихы” бүлегендә “Авылым ядкәрләре” дигән стенд урнаштырылды. Стендның эчтәлеге авылларыбыз территориясендә урнашкан истәлекле урынннар турында бара. Аларның фотосурәтләре урнаштырылды. Шулай ук бу бүлектә авыллар тарихы, аларның килеп чыгу тарихы белән бәйле риваятьләр белән танышырга мөмкин.

**Проектны тормышка ашыру этаплары:**

1. **Информацион – мотивацияле**. (2017-2018)

Максаты: Туган яныбызда булган төрле вакыйгалар, авыллыр тарихы, гореф-гадәтләрне барлау.

Бурычлары:

- бердәнбер чыганак өлкән яшьтәгеләрнең истәлекләре, хәтерендә калганнары, буыннан-буынга сөйләнеп килгән хатирәләр, вакыйгаларны барлау;
- җирлектәге өлкән буын кешеләреннән үткән тарихыбыз турында информация җыю;
- иҗат төркемнәре булдыру һәм бу этапта төп нәтиҗәләр эзләнү эшләренең максаты, бурычлары һәм проблемаларын ачыклаудан торды.

2. **Практик этап** (2018-2019)

Максаты: Туган якның, туган авылның, туган мәктәпнең тарихында булган вакыйгаларны мәктәп музее экспозицияләренә, фәнни эшләрдә чагылдыру,аны буыннан буынга саклап калдыру,балаларда иҗат итү, эзләнү омтылышы булдыру.

Бурычлары:

- максат һәм бурычларны тормышка ашыру өчен төп бүлекләрне үз эченә алган юнәлешләрдә эшләү;
- иҗат төркемнәре белән тикшеренү эшләре эшләү;
- авыл халкы арасына чыгып, авыл, мәктәп тарихы турында, авылның күренекле кешеләренә багышланган материаллар, фоторәсемнәр, экспонатлар туплау

Мөстәкыйль рәвештә эзләнү эшләренең әһәмиятен бәяләп бетерергә мөмкин түгел. Чөнки алар проблеманы үзләре формалаштыралар һәм максат-бурычларны да үзләре куялар, чишү юлларын билгелиләр. Иҗади тикшеренү эшләре эшләгәндә укучылар үзләренең туган як турындагы белемнәрен үстерәләр, үткәнгә, тарихыбызга, гореф-гадәтләргә кызыксынуларын арттыралар.

3. **Гомумиләштерү** этабы (2020-2021)

Максаты: Теоретик яктан өйрәнелгән һәм практик яктан тикшерелгән материаллар белән төрле мероприятияләр аша тәҗрибә уртаклашу.

Бурычлары:

- методик пособияләр булдыру;
- район һәм республика күләмендә үткәрелә торган чараларда катнашу;
- тикшеренү эшләре белән фәнни-гамәли конференцияләрдә катнашу;

4. **Йомгаклау** (2021-2022)

Максат: тупланган мәгълүматны берләштереп, туган якны өйрәнү музеенда эшкәртмәләр ясау, брошюралар чыгару.авылым видеосын эшләү.

**Проектның эчтәлеге**

Туган якны өйрәнүтарихи һәм географик юнәлешләрне берләштерүдән гыйбарәт.

**Әй, мәктәбем-белем учагы, син гомернең иң гүзәл чагы!.**Мәктәптәбебез тарыхы. Мәктәпнең киләчәге Бөрбаш мәктәбе укучысы кодаксын төзү. Мәктәптән чыккан һөнәр ияләре, мәктәпне данлаган шәһесләребез, укыткан укытучылар, хезмәткәрләр.

**Нәсел тамырым тирән минем, ерак гасырлардан башлана.** Нәрсә ул шәҗәрә? Шәҗәрә төзү. Гаилә туграсы төзү. Нәселебезнең тарихи ядкәрләре.

**“Туган җирем, үскән җирем, гади генә бер авыл”.** Халкыбызның милли бәйрәме Сабантуй, аулак өй, каз өмәсе, “Карга боткасы” бәйрәме, Нәүрүз, Яңа ел бәйрәме. Дини йолалар һәм бәйрәмнәр. Авылыбыз фольклоры: бәетләр.

**Авылым - минем язмышым.**Авыл һөнәрләре. Һөнәр ияләре белән очрашу. Хезмәт алдынгылары.

**Беркем дә онытмады, бернәрсә дә онытылмас.** Исәннәрнең кадерен бел. Авылдашларыбыз Бөек Ватан сугышында. Сугыш елларында тыл хезмәткәрләренең тормышы. Һәйкәлләргә чәчәк куйыйк.

**Проектның чаралары**

| **Эш формасы** | **Чаралар** |
|---|---|
| Иҗади проект | Ядегәр мәктәбе укучысы кодексын төзү, шәҗәрә төзү,гаилә туграсы төзү,авылыбызның киләчәге нинди. Туган төбәгем- Ядегәр җирлеге. Мәктәп тарихы. Атамалар тарихы. Шәҗәрәләрдә - гаилә тарихы. |
| Альбом төзү | Мәктәптән чыккан һөнәр ияләре, мәктәпне данлаган шәһесләребез, укыткан укытучылар, хезмәткәрләр. Авылыбыз фольклоры: бәетләр. Авыл һөнәрләре.Сугыш елларында тыл хезмәткәрләренең тормышы. Халкыбызның милли бәйрәме Сабантуй. Аулак өй, каз өмәсе. “Карга боткасы” бәйрәме. Нәүрүз, Яңа ел бәйрәме. Дини йолалар һәм бәйрәмнәр. Авылдашларыбыз Бөек Ватан сугышында |
| әңгәмә | Нәрсә ул шәҗәрә? Авыл язмышы безнең кулда. Тарихи чыганаклар авылларыбыз турында сөйли. Һөнәр ияләре белән очрашу. Исәннәрнең кадерен бел. |

| | |
|---|---|
| Мәгълүмат туплау | Ядегәр авылы тарихы. Хезмәт алдынгылары. |
| Күргәзмә | Нәселебезнең тарихи ядкәрләре |

**Йомгаклау**

Гомер уза, еллар үтә. Тарих тәгәрмәче алга тәгәри. Кешелек ашыга-ашыга киләчәккә атлый. Тик бер генә мизгелгә артка карыйк әле, халкыбыз нинди дәвер, чорлар аша үтте икән?Һәр халык үзенең традицияләре, гореф-гадәтләре белән бай. "Үткәнен белмәгән халыкның киләчәге юк",- диләр. Дөрес сүзләр. Шуңа күрә хәзер көнкүрешебезгә төрле йола-бәйрәмнәр кире кайта ("Нәүрүз", "Карга боткасы", "Каз өмәсе" һ.б.) күбрәк үтеп керә халык хәтере булып, музейлар барлыкка килә, яңара.

Туган илгә мәхәббәт, халкыбызның үткәндәге истәлекләрен хөрмәт итү, хәзерге казанышларына ихтирам һәм горурлык хисләре,милли аң тәрбияләүдә,укучыларга патриотик тәрбия бирүдә туган якны өйрәнү зур әһәмияткә ия. Проект шулай ук туган якның, туган авылның, туган мәктәпнең тарихын өйрәнү, аны буыннан буынга саклап калдыруда һәм укыту-тәрбия эшендә зур ярдәм итә.

*Кулланылган әдәбият*


1. ЗамалиеваЗ.А. сост. **Народные обряды и праздники татар** /НБ РТ;Отв. ред. И.Г.Хадиев.- Казань: Милли китап, 2000.- 42 с.- (В библиотеках республики: Из опыта работы; Вып. 4).-На татар.яз.
2. ЗамалиеваЗ.Асост..; **Обычаи и праздники татар** /НБ РТ: Отв. ред. И.Г.Хадиев.-Казань: Милли китап, 2003.-31 с.- (В библиотеках республики. Из опыта работы; Вып. 2).- На татар.яз.
3. ЗуеваО.И.**Отдел искусств: перемены на фоне традиций**: Сборник /НБ РТ; Отв. ред. Р.У.Багаева.-Казань: Милли китап, 2003.-42 с.
4. Артемьев А. Древний булгарский город Жукотин. – СПб 185.
5. Гарипова Ф. Авыллартарихыннан. – Казан, 1997.
6. Ислаева Ф. Шәҗәрә. – Идел, 2000 №6.
7. Татар энциклопедиксүзлеге. (Баш редакторы М.Х.Хасанов) – Казан АН РТ Татар энциклопедия институты 1999.
8. Чернышев Н.Г. Селения казанского ханства по писцовым книгам – Казан 1971.
9. Шиһабетдин Мәрҗани. Мөстафадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар - Казан 1989.
10. Әхмәтҗанов М.И. Шәҗәрәне ничек төзергә – Идел 2000 №2.


## САНЛЫ ТИГЕЗЛЕК ҺӘМ ТИГЕЗЛӘМӘ
### 2нче сыйныфта математикада дәресе


*Нигаматуллина Раилә Мәхмүт кызы,*
*Янил уртамәктәбенең Вахит авылы филиалы,*
*Кукмара районы*


**Максат**: Яңа математик төшенчә- "тигезләмә" төшенчәсе белән таныштыру, билгесез санның кыйммәтен сайлап алу юлы белән табарга өйрәтү.

**Бурычлар**: Тигезләмәләрне башка төр аңлатмалар арасыннан таба белү; телдән исәпләү, дөрес тигезлекләр төзү, мәсьәләләр чишү күнекмәләрен камилләштерү;

игътибарлылык, хәтер үсешен формалаштыру; тигезләү күнекмәләрен, танып белү, логик фикер йөртү эшчәнлекләрен, активлыкларын үстерү.

Игьтибарлылык, тырышлык, математика фәнен өйрәнүгә кызыксыну тәрбияләү.

**Универсаль уку гамәлләре формалаштыру:**

*Шәхескә кагылышлы УУГ:*

Уку эшчәнлегенең уңышлар критериесе нигезендә үзбәяләү сәләте формалаштыру.

*Регулятив УУГ:*

Укытучы ярдәмендә дәреснең максатын билгели һәм формалаштыра белү; дәрестәге гамәлләр эзлеклелеген әйтү; күмәк төзелгән план буенча эшләү, үз фикереңне дөрес итеп әйтү.

*Коммуникатив УУГ:*

Үзеңнең фикереңне телдән матур итеп әйтә белү; башкаларны ишетә һәм тыңлый белү;

*Танып-белү УУГ:*

Танып белү максатын билгеләү; кирәкле информация туплау; үткәндә өйрәнгәнне яңасыннан аера белү; дәреслектән, тормыш тәҗрибәңнән, дәрестә алган информациядән файдаланып сорауларга җавап бирү.

**Планлаштырылган нәтиҗә**

*Предметлы:*

“Тигезләмә” төшенчәсе белү.

Билгесез санның кыйммәтен сайлап алу юлы белән таба белү.

Тигезләмәләрне башка төр аңлатмалар арасыннан аера белү;

*Шәхескә кагылышлы:*

Иптәшеңә ярдәм итүдә танып-белү инициативасы, үз-үзеңне бәяли белү.

*Метапредметлы:*

Укытучы ярдәмендә дәреснең максатын билгели һәм формалаштыра белү; дәрестәге гамәлләр эзлеклелеген әйтү; күмәк төзелгән план буенча эшләү; үз фикереңне дөрес итеп әйтү;( *Регулятив УУ):*

Үзеңнең фикереңне телдән матур итеп әйтә белү; башкаларны ишетә һәм тыңлый белү; мәктәптә аралашу кагыйдәләре турында сөйләшү һәм аны үтәү. *(Коммуникатив УУГ)*

Үзеңнең белем системасында ориентлаша белү; үткәндә өйрәнгәнне укытучы ярдәмендә яңасыннан аера белү; яңа белемнәр табу; дәреслектән, тормыш тәҗрибәңнән, дәрестә алган информациядән файдаланып сорауларга җавап бирү. *(Танып-белү УУГ)*

**Теманың төп эчтәлеге,терминнар, төшенчәләр** : тигезләмә, Х, сан

**Дәрес тибы** Яңа белемнәр үзләштерү.

**Кулланмалар : төп -** Дәреслек. А.Л.Чекин «Математика», 2сыйныф., 2 яртыеллык..Тема: “Санлы тигезлек һәм тигезләмә”,

**өстәмә** - проектор, слайдлар, ноутбук, презентация, язулы кәгазьләр

**Эш төре:** фронталь,индивидуаль, парлардаэш.

**I этап. Оештыру өлеше.**

Елмайдык, барыбызга да бик рәхәт булып китсен әле.

Елмаям мин кояшка, укытучы апама,

Елмаямын дусларга ,

Елмаям бар дөньяга!

Безнең шушы яхшы кәефләребез көн буена саклансын.

Барыбыз да борылып күзләрегез белән иң ерак ноктаны билгелибез. Билгели алдыгызмы? Ә хәзер тагын да ныграк борылып карыйк. Кемнең карашы тагын да ераграк ноктага юнәлде? Буламы? Менә күрдегезме, кеше үзе тели икән, ул барысына да ирешә ала. Мин дә сезгә бу дәрестә күп нәрсәләргә ирешүегезне, белемегезне тагын да арттыруыгызны телим.

Хәерле көн, балалар! Математика дәресен башлап җибәрәбез .

Бүген дәрестә без яңа белемнәр алырбыз. Бер – беребезгә булышырбыз.

-Ә безнең бүгенге кунагыбыз кем? (Кояш) Ләкин кояшның нурлы карашы өчен нәрсәдер җитми? (нурлары) Кояш үзенең нурлары белән безгә дәрестәниләр эшләргә икәнен юнәлеш биреп торачак, без һәрбер эшне эшләп нурларын үзенә бүләк итеп барачакбыз.

1. Телдән исәпләү, кабатлау.
2. Яңа тема үзләштерү.
3. Дәрестә өйрәнгәннәрне ныгыту.
4. Үзконтроль.
5. Үзбәя. Өй эше.

Әйдәгез, дәрестә утыру кагыйдәләрен искә төшерик.. Игътибарны дәрескә юнәлтик.. Укучылар, бүгенге дәресебез нинди булсын? (кызыклы, мавыктыргыч)

- Моның өчен нәрсә эшләргә кирәк?(тырышырга)

- Әйдәгез эле , укучылар, хәзер бераз экранга игътибарыбызны юнәлтеп алыйк.

**?**


Сезгә тәкъдим ителәчәк бу рәсем безгә алга таба дәресебездә кирәк булачак әле. Ни өчен кирәклеген алга таба сез әйтерсез. Бик игътибар белән карагыз.

**II этап. Белемнәрне актуальләштерү.**

**1)** Санлы аңлатманың компонентларын атагыз:
20+7=27
37-5=32
3*7=21
(сигнал карточкалары ярдәмендә күрсәтәләр)

**2)** Аңлатмаларның кыйммәтен табыгыз:
22+2=
13+20=
40-7=
63-20=

**3)** Тапкырлауны кабатлау. Перфокарталар белән эш. Эшләп бетергәч кәгазьләрен алыштырып иптәшләренекен тикшерәләр.(мэнэдж-мэт)

- Без алдагы дәрестә өйрәгәннәрне кабатладык, телдән исәпләдек. **Эшебезне тиешенчә башкара алдыкмы? Кояшка нурын бүләк итәбезме?**

- Укучылар, мин сезгә карточкалар бирәм. Бу карточкадагы язмаларга нинди исем куеп булуын ачыклагыз.

– Тактада сез язулы кәгазьләр күрәсез. Санлы тигезлек, тәрәзәле мисал, тигезсезлек. Үз язмаларыгыз нинди исемгә ия булуына карап, тиешле язу астына куегыз.

| | | |
|---|---|---|
| 17+6=23 | 89>60-4 | 47+5>36 |
| +10=17 | +4=16 | 76<26-9 |
| +9=36 | 25+3=28 | 49-6=43 |
| X+4=12 | | |

Язмаларны куябыз да утырабыз. Ә менә ул үзенең язмасын кайда куярга белмәде, әйдәгез, ярдәм итик әле.

X+4=12

-Бу язма ничек атала? Әйдәгез, без аны тактага беркетеп куеп торыйк.

– Рәхмәт, урыныңа утыр.

**IIIэтап. Яңа материалны аңлату.**

**1. Уку проблемасын кую.**

-Без мондый аңлатмаларны беләбезме? Безнең алдыбызга нинди проблема килеп туа?

-Мин сезгә уен тәкъдим итәм. Бу уенны без төркемнәрә уйнаячакбыз. Сезгә карточкаларда саннар бирелә, ул сан алфавиттагы хәрефнең урынын билгели.

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 4 | 2 | | | 1 | 5 | | 6 | |
| | | | | | | | | |

Алфавитны искә төшереп тиешле сан астындагы хәрефне язалар.

Менә хәрефләрне тездегез, билгесез аңлатманың исеме килеп чыкты. (ТИГЕЗЛӘМӘ) Тигезләмә сүзе тактага эленә.

-Молодцы, балалар, димәк без бүгенге дәресебезнең темасы ничек булачак?

-Алдыбызга нинди максатлар куярбыз?

**2. Яңа белемнәрне ачу**

- Ә нәрсә ул тигезләмә, без аңа җавап таба беләбезме?

-Әйдәгез, алайса без бүген сезнең белән **галим-эзләнүчеләр** булыйк, бергәләп тигезләмәнең нәрсә булуын, аны чишү юлларын ачыкларбыз. Сез ризамы?

-Игътибар белән карыйк әле. Тигезләмә без белгән нинди язмага ошаган? (Тәрәзәле мисал)

Тәрәзә урынына латин хәрефе X куелган. Әйдәгез, нәрсәләр беләбез икән бу язылыш турында?

-Бу тигезлек, чөнки = тамгасы бар.

-Бу нинди тигезлек? (сумманы табу)

-Барлык саннар да билгелеме? (1 кушылучы билгесез)

-Ул нәрсә белән билгеләнгән? (латин хәрефе х белән)

- X аңлатмада нәрсә ул? (билгесез сан) Ул башка аңлатмаларда бармы? (юк)

- Шулай булгач нәрсә соң ул тигезләмә, әйтеп карыйк әле.

**Тигезләмә** –билгесез саны(X) булган тигезлек (=) ул.

Китапның 75нче битен ачабыз да кагыйдәне табабыз ,үзебез ясаган нәтиҗә белән чагыштырабыз. Без тигезләмәнең нәрсә икәнен белә алдыкмы? Әйдәгез хәзер парларда бер-берегезгә тигезләмә турында сөйләгез.

X+4 = 12 –нәрсә булды инде ( тигезләмә)

-X нәрсә әле? Билгесез санны нишләтергә кирәк (табарга)

-Тигезлек дөрес булсын өчен нинди сан куярбыз?(8, чөнки 8+4 =12)

-Ә сез 8 санын ничек таптыгыз? (4+8, 12-4)

-X ничәгә тигез булды? (8)

Тигезләмәдә табыла торган сан **тигезләмәнең тамыры** дип атала.

-Менә эле генә сез тигезләмәне чиштегез, сез бик яхшы галим-эзләнүчеләр икән

- **Без яңа дәресне үзләштерә алдыкмы? Кояшка нурын бүләк итәбезме?**

<u>**Физкультминутка:**</u>

- Ә сез кышны яратасызмы?

-Яратабыз.

-Кыш көне нәрсә күп була?
-Кар.
- Ә хәзер кар бөртекләрен учыбызда уйнатыйк.

**Кар бөртеге**

Кар бөртеге очып керде,
Менә шулай очып йөрде,
Чүгәләде, өскә менде,
Уңга килде, сулга килде.
Кар бөртеге бик аз очты,
Суздык аңа җылы учны,
Салмак кына ул утырды.

**IV этап. Өйрәнгәннәрне ныгыту..**

1)-Ә хәзер китапның 76 битен ачтык. №2 не эшлибез. Дәфтәрләрне ачтык. Числоны яздык. Матур язу күнегүе – 247 санын язу.

№2 (76 бит) Биремне укыйбыз.

38-X=20

- Тигезләмәнең тамыры ничәгә тигез булды?

2) № 4 (76 бит)

- Әйдәгез бергәләп тигезләмә төзик.

75-X=45

3)Укучылар белән практик эш.

Укучының 3 карандашы бар иде. Укытучы аңа коробка белән карандашлар бирде. Укучының 9 карандашы булды. Нинди сорау куярбыз?

-Әйдәгез, укучылар, шушы мәсьәләне тигезләмә төзеп чишик. Безнең нәрсә билгеле? 3 карандашы бар. Тагын нәрсә билгеле? Барлыгы. 9. Ә нәрсә билгесез? Аны ничек билгеләрбез? X белән. Әйдәгез тигезләмә төзеп карыйк. 3+X=9

4) - Дәрес башында караган рәсемне искә төшерегез әле. Мин сезгә: “Алга таба дәресебездә кирәк булачак әле”, - дигән идем.




-

-Шушы рәсем буенча тигезләмә төзеп карыйк әле. Карбызның массасын табарга кирәк. Бергәләп мәсьәләне тигезләмә төзү юлы белән чишик. Монда нинди тигезлек үтәлергә тиеш? Укучылар ул тигезлекне чыгып язалар.

X+2=5

Безгә тормышта тигезләмәләр чишәргә туры киләчәкме? (кибеттә)

**- Без дәрестә өйрәгәннәрне ныгыттык. Эшебезне тиешенчә башкара алдыкмы? Кояшка нурын бүләк итәбезме?**

**V. Контроль ясау.**

-Ә хәзер үтелгәннәрне кабатлап алырбыз. Мин сезгә карточкалар бирәм , шул карточкаларда эшлибез.

1. Бирелгән саннарны, тамгаларны кулланып бер тигезләмә төзергә.

4, 7, X, +,=

2. Язмалар арасыннан тигезләмәнең астына сызарга.

3+ =7 45>34+1 X-6=12 34-23=11

3. 5, 7, <u>9 </u>саннарының кайсысы 17+X=26 тигезләмәсенең тамыры булып тора? Шул санның астына сызарга.

Үзконтроль үткәрү. Слайдтан дөреслеген тикшерү,эшләрнең барысы да дөрес булса – яшел , 1-2 хата булса- сары, 3 хата булса – кызыл түгәрәк ясарга.

**- Без эшебезне тиешенчә башкара алдыкмы? Кояшка нурын бүләк итәбезме?**

**VI. Дәрескә йомгак. Эшчәнлек рефлексиясе**

1)Галим-эзләнүчеләр буларак без бүген нәрсәләр өйрәндек?

- тигезләмәнең нәрсә икәнен (табарга тиешле билгесез саны булган тигезлек ул)

- тигезләмәнең ничек чишелешен

-тигезләмә чишү алгоритмын

2) Үзләрен бәялиләр. Үзегезнең дәрестәге эшчәнлегегезне бәяләгез.

Кызыл,яшел, сары түгәрәкләр белән бәяләнгән карточкаларны алдык. Кемнең эшләгән карточкасында яшел белән билгеләнгән яшел түгәрәк, кемнең сары икән сары түгәрәк, кемнең кызыл икән кызыл түгәрәк күтәрәчәкбез.

Укучылар, сез үзегезнең белемегезне бәяләдегез, кемнең яшел түгәрәк – 5ле, кемнең сары түгәрәк -4ле, кемнең кызыл түгәрәк 3ле билгесе куярбыз.

3)Өй эше

-№5 (76 бит) - китаптан

- иҗади-эзләнү эше: тигезләмә чишә белү тагын нинди һөнәр ияләренә кирәк булуын белеп килергә;

**- Без кояш нурларындагы барлык эшләрне дә башкарып чыга алдыкмы? Кояш безне каршы алган иде, җылы карашы белән озатып та кала, дәрес тәмам, чыгарга мөмкин.**

## УМНОЖЕНИЕ ДЕСЯТИЧНЫХ ДРОБЕЙ

*Низамова Наиля Ильгизовна,*
*МБОУ КСШ №4 Кукморский район*

**Цели урока:**

- повторить правило умножения десятичной дроби на натуральное число;
- вывести правило умножения десятичной дроби на десятичную дробь;
- закрепить материал с помощью решения различных упражнений;
- расширять кругозор учащихся;
- развитие познавательной активности, положительной мотивации к предмету;
- воспитание патриотических чувств, любви к Родине.

**Тип урока**: изучение и первичное закрепление новых знаний.

**Форма урока:** урок-путешествие

**Технология:** игровая

**Оборудование**: презентация, мультимедийный проектор, учебник, карточки для работы в группе, индивидуальные карточки, опорные сигналы, менеджмент, листы А4 на каждого.

Ход урока

**1. Мотивация к учебной деятельности.**

Здравствуйте, ребята! Я надеюсь, что вы пришли на урок математики в хорошем настроении. Будете помогать мне, а я вам, будем работать одной дружной командой, и у нас всё обязательно получится! Сегодня мы с вами познакомимся с новой темой, но тему урока вы сформулируйте сами. Каждый из вас сможет показать свой уровень знаний, а также повысить его. А поможет вам в этом – путешествие. Какое это путешествие, вы ответите сами, решив правильно следующие примеры.

**2. Этап актуализации и пробного действия.**

1. Поработаем устно.

Задание. Найдите лишнее число в каждой группе:

1,5 2,354 4 7,61

79 0,5 19

Задание. Найти площадь прямоугольника.

а = 12см, в = 5 см

Задание. Вычислите и найдите соответствующие буквы, составьте слово. Выполним это задание, применяя структуру Релли Робин. У вас есть 30 сек чтобы подумать. Время вышло. Все успели? Работаем с партнером по плечу. По 15 сек дается партнеру А и Партнеру Б. Закончили. Отвечает стол № участник № . Какое у вас получилось слово? Правильно: ПОБЕДА.

1) 1,5 • 5=7,5 (П)

2) 2 • 2,4=4,8 (О)

3) 0,36 • 2 = 0,72 (Б)

4) 7,8 • 1 = 7,8 (Е)

5) 0,3 • 12= 3,6 (Д)

6) 0,15 • 3 = 0,45 (А)

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 0,72 | 7,8 | 3,6 | 7,5 | 0,45 | 4,8 |
| Б | Е | Д | П | А | О |

Ребята, с какой крупной датой нашего государства связано слово ПОБЕДА?

В 2018 году 9 мая исполнится 73 года Победы в Великой Отечественной войне нашего народа над фашистскими захватчиками. И мы с вами в честь этого большого события совершим путешествие по городам-героям.

Путешествие будет увлекательным и познавательным. Вас ждут испытания. Чтобы их преодолеть, понадобятся знания и смекалка, дружба и находчивость, быстрота и аккуратность выполнения заданий.

В этом путешествии я буду экскурсоводом, а вы экскурсионной группой.

**3. Этап выявления места и причин затруднения.**

**Брест – отважный город герой.**

Первый удар немецкой армии приняли на себя 22 июня 1941 года в 4 часа ночи

жители Брестской крепости. Началась Великая Отечественная война, которая длилась 1418 дней и ночей.

Защитники Брестской крепости сумели продержаться долгие 6 недель. К сожалению, почти все они погибли. Город Брест был освобожден Красной Армией 28 июля 1944 года.

Брестская крепость в форме прямоугольника. Длина равна 2,8 км, ширина 1,5 км

**а=1,5 км**

**b=2,8 км**

Найти площадь Брестской крепости. (Площадь Брестской крепости нужно было

знать для того чтобы правильно распределить солдат на всей местности, чтобы потерь было меньше. В мирное время тоже и военные, и работники полиции обязательно сначала находят площадь, только потом распределяют своих работников. Так же работали на Универсиаде в Казани).

Как найдем? S = a•b

S = 1,5км •2,8 км

С какой трудностью вы столкнулись?

- мы не умеем умножать десятичные дроби на десятичные дроби. Значит, чем мы

будем заниматься, и какая у нас будет тема урока?

**«Умножение десятичной дроби на десятичную дробь»**

Ребята, давайте поставим себе цель, чему мы должны научиться?

**4. Этап построения проекта выхода из затруднения.**

Давайте решим нашу задачу в целых числах, для этого длину и ширину Брестской крепости нужно перевести в другую единицу измерения, если вы забыли единицы измерения, то можете посмотреть в опорных сигналах.

Опорные сигналы

1км = 1000 м

1 кв км = 1000000 кв метр

**5. Реализация построенного плана**

Итак S = 1,5км •2,8 км = 1500 м• 2800м=4200000 кв. м= 4,20 кв.км

Ребята, как мы умножили десятичную дробь на десятичную дробь? Давайте, попробуем составить алгоритм.

***<u>Чтобы умножить одну десятичную дробь на другую надо:</u>***

***1. Перемножить их, не обращая внимания на запятые;***

***2. Отделить запятой в произведении столько цифр <u>справа</u> сколько их стоит после запятой в <u>обоих множителях вместе</u>***

**6. Первичное закрепление во внешней речи**

Город-герой Москва.

Ребята, а сейчас мы с вами полетим в город-герой Москву.

1. Чтобы время в самолете пролетело быстро, мы с вами порешаем задачи.

**Задача**. Рассчитаем расстояние от Бреста до Москвы, если известно, что скорость самолета 830,5 км/ч, время полета 1,2 км/ч.

830,5 *1,2 = 996.6 (км)

Молодцы. Как вы умножили десятичные дроби? (проговаривание). У нас ещё есть время до Москвы. Давайте, проверим как вы все усвоили новую тему.

**7. Самостоятельная работа с самопроверкой по эталону**. (Структура Сималтиниус Релли Тэйбл. 2 ученика одновременно выполняют письменную работу на отдельных листочках и по окончанию одновременно передают друг другу. Работа с партнером по плечу)

Поставьте правильно запятую.

1,27 • 3,5 = 4445
12,7 • 0,35 = 4445
12,7 • 3,5 = 4445
0,127 • 3,5 = 4445
0,127 • 0,35 = 4445
1,36 • 3,4 = 4624
13,6 • 3,4 = 4624
1,36 • 0,34 = 4624
0,136 • 0,34 = 4624
1,36 • 3,4 = 4624

**8. Включение в систему знаний и повторение.**

Вот мы и приехали. Перед нами Москва, где 24 июня в 1945 году был парад Победы.

30 сентября 1941 г. фашистские генералы отдали приказ о наступлении на Москву. План своего наступления фашисты назвали «Тайфун». Тайфун – сильный ветер, ураган, сметающий все на своем пути.

Началось одно из крупных сражений Великой Отечественной войны. Вся страна встала на защиту столицы.

**<u>Задача:</u>** В октябре и ноябре 1941 г. фашистские войска предприняли два крупных наступления на Москву. В первом бою участвовали 1,2 миллиона советских солдат и офицеров. Силы противника превосходили в 1,5 раза. Сколько немецких солдат и офицеров участвовало в наступлении?

Несмотря на превосходящие силы противника, наши войска отстояли столицу. Разгром немцев под Москвой имел огромное значение. На полях Подмосковья был развеян миф о непобедимости германской армии.

**<u>9. Рефлексия</u>**

Хорошо, молодцы!

Во время путешествия мы с вами посетили два города - героя:

**Город-герой Брест**

**Город-герой Москву**

Подведение итогов.

- Каждый из вас сегодня заработал награды в виде звезды. Давайте подведем итоги.

Сделаем из них салют.

Домашнее задание творческое.

К сожалению, у нас ограничено время. А мне так понравилось работать с вами. Большое спасибо. Наш урок подошёл к концу.

## ПРОЕКТНАЯ ДЕЯТЕЛЬНОСТЬ ВО ВНЕУРОЧНОЕ ВРЕМЯ, КАК СРЕДСТВО РАЗВИТИЯ ПОЗНАВАТЕЛЬНОЙ АКТИВНОСТИ УЧАЩИХСЯ НАЧАЛЬНЫХ КЛАССОВ

*Николаева Эльвира Николаевна,*
*учитель начальных классов*
*МБОУ «СОШ с.Манзарас»*
*Кукморского муниципального района РТ*

Проектная деятельность:

- учит детей ставить и решать проблемы, которые требуют не только применение полученных знаний, но и приобретения новых в рамках самостоятельного и совместного со взрослыми исследования;
- раскрывает личностные качества;
- повышает самооценку, интерес к учебной деятельности;
- помогает школьникам чувствовать себя уверенно в нестандартных ситуациях;
- повышает адаптивные возможности и творчество.

**Основные понятия.**

Проект- в буквальном переводе с латинского- «брошенный вперёд».

В словарях- план, замысел, текст или чертёж чего- либо, предваряющий его создание.

Проект- прототип, прообраз какого- либо объекта, вида деятельности и т.п., а проектирование превращается в процесс проекта.

**Классификация проектов:**

- по количеству учащихся: индивидуальные, парные, групповые, коллективные;
- по продолжительности: краткосрочные, средней продолжительности, долгосрочные;
- по результатам: поделки (игрушки, книги, рисунки, открытки, костюмы, макеты, модели и т.д.), мероприятия (спектакли, концерты, викторины, КВН, показы мод и т.д.);
- по месту проведения: урочные, внеурочные.

Во внеурочной деятельности работали над проектом «Убранство избы».

Проект «Убранство избы» сложился из ряда уроков, посвящённых работе над изделиями: русская печь, коврик, стол и скамья. (Приложение №1)

Этапы работы над проектом.

**I этап. Подготовительный.**

В начале каждого урока учащиеся знакомятся со статьёй учебника, в которой рассказывается о людях, чья профессия связана с данным видом деятельности. Дети знакомят одноклассников с интересными фактами, традициями, поверьями, относящимися к теме урока. При подготовке учащиеся используют энциклопедический словарь, материалы сети Интернет. Предварительная подготовка обучающихся к уроку является ознакомлением с тематикой уроков и ребята, как правило, знают, какое изделие им предстоит выполнить на уроке.

До начала урока ученики рассаживаются в группы, как правило, это группы, сформированные дружескими привязанностями, которые, однако, способствуют взаимопомощи при выполнении изделия. Если изделие представляет собой комплексную работу, дети распределяют между собой обязанности. Итогом становится одно общее изделие.

Подготовительный этап решает задачу речевого развития детей, выработки навыков анализа и планирования работы, поэтому на этом этапе учитель обсуждает с детьми все этапы работы, обратив внимание на те, выполнение которых требует от учеников наибольших усилий. После определения цели составляется чёткий, конкретный план работы.

**II этап. Основной (деятельностный).**

Данный этап работы - самостоятельная деятельность учащихся. В учебнике планы всех изделий представлены в краткой форме под заголовком «План работы», приведён алгоритм его выполнения в фотографиях или рисунках. Это помогает ученику контролировать последовательность действий и распределять деятельность при групповой работе.

Роль учителя на данном этапе заключалась только в повторении правил и приёмов работе с материалами и инструментами. Для облегчения выполнения заданий в рабочей тетради даны развёртки деталей, шаблоны, необходимые для создания поделок, которые ребёнок должен вырезать и использовать для изготовления поделки. Рабочая тетрадь составлена в соответствии с темами учебника. В ней представлены материалы для практических работ, экспериментов, описания проектов, которые помогут сделать работу на уроке интереснее и продуктивнее, значительно разнообразив её.

В ходе занятий по изготовлению доступных ребёнку изделий развивается его глазомер, мелкие мышцы руки, речь и необходимые практические умения и навыки. Кроме того, ребёнок учится подготавливать рабочее место, настраиваться на продолжительную работу, слушать объяснение, выполнять в соответствии с инструкцией необходимые действия, доводить начатое до конца. Всё это поможет в решении главной задачи начального обучения-научить ребёнка учиться, а это позволит в дальнейшем использовать полученные знания и умения в реальной повседневной жизни.

Однако практическая деятельность является лишь средством развития социально значимых личностных качеств школьников, формирования системы специальных технологических и универсальных учебных действий.

**III этап. Презентация.**

После реализации плана целесообразно оформить работу и провести её презентацию. Такая работа способствует развитию речевых навыков учащихся, умений самоанализа и самоконтроля. Это может быть выставка поделок, демонстрация работ учителем или учащихся, оформление работы для папки достижений, но с одним обязательным условием-обсуждением и оценкой результатов работы.

В процессе презентации изделия школьник учится строить монологическое высказывание, рассказывая о цели изготовления изделия и вариантах его использования. В ходе оценки проекта учащиеся должны научиться отвечать на вопросы: «Что нового вы узнали? Чему научились? Как вы этого сделали?», т.е. научиться анализировать и оценивать свою работу.

Обучение работе над проектом позволяет развить различные способности ребёнка: личностные, коммуникативные, технологические, социальные, художественные и др. Проектируя, ребёнок учится формулировать цель, соотносить поставленную цель с условиями её достижения, выстраивать программу действий в соответствии с собственными возможностями, добиваться реализации цели, безусловного завершения работы, различать виды ответственности внутри своей учебной деятельности.

**IV этап. Заключительный.**

После завершения работы следует проанализировать и оценить выполненное изделие. Всё это поможет ребёнку осознать важность своего труда, осмыслить процесс выполнения работы, допущенные ошибки и достижения. Это послужит мотивацией к работе, будет способствовать развитию трудовых навыков учащихся, речи, познавательных способностей и умения учиться. С этой же целью полезно предлагать ребёнку рассказать кому- то (брату, сестре, бабушке и др.), как он работал над изделием, что было особенно трудно, что получилось хорошо, а что не удалось.

Презентация результатов проекта и его оценка являются обязательными компонентами проектной деятельности. При этом надо учитывать, что оценка является относительным понятием в этом возрасте и должна носить позитивный характер, т.е. указания на ошибки могут быть только в форме предложений по их исправлению.

## КУРС ВНЕУРОЧНОЙ ДЕЯТЕЛЬНОСТИ КРАЕВЕДЧЕСКОГО КРУЖКА «МОЙ РОДНОЙ КРАЙ»

*Нургалиева Чулпан Рафаилевна,*
*учитель английского языка МБОУ*
*"Большекукморская средняя школа*
*с угублённым изучением отдельных предметов"*
*Кукморского района РТ*

Программа разработана в соответствии:

- с Законом РФ «Об образовании в Российской Федерации»;

- Федеральным государственным образовательным стандартом начального общего образования (утвержден приказом Министерства образования и науки Российской Федерации от 06.10.2009г. № 373);

- Федеральным государственным образовательным стандартом основного общего образования (утвержден приказом Министерства образования и науки Российской Федерации от 17.12.2010г. № 1897);

- санитарно-эпидемиологических требований к условиям и организации обучения в ОУ (утверждены постановлением Главного государственного санитарного врача РФ от 29.12.2010г. №189);

- положения о структуре, порядке разработки и утверждения рабочих программ курсов внеурочной деятельности

Актуальность данной программы заключается в том, что в настоящее время наблюдается повышенный интерес к изучению родного края. Изучение краеведения в начальной школе является одним из основных источников обогащения учащихся знаниями о родном крае, воспитание любви к нему, формирование гражданских позиций и навыков. Оно играет существенную роль в нравственном, эстетическом, трудовом, политическом воспитании, является, интегрирующим звеном между учебной и воспитательной деятельностью школы и обеспечивает межпредметные связи.

Актуальность разработанной программы продиктована также отсутствием в теории и практике краеведческого образования в начальной школе единой, рассчитанной на весь период обучения, программы дополнительного образования с краеведческой направленностью для младших школьников.

Программа «Мой родной край» имеет **духовно-нравственную направленность** и представляет собой вариант программы организации внеурочной деятельности школьников.

Программа представляет собой интегрированный курс, имеющий **целью** ввести учащихся в мир истории и культуры наших предков.

**Задачи программы:**

***образовательные:*** структура программы позволяет формировать у школьников общее представление об истории родного края, о культуре, о ее богатстве и разнообразии;

***развивающие:*** развивать в детях наблюдательность, самостоятельность и инициативу; развивать у детей способности проявлять свои теоретические, практические умения и навыки;

***воспитательные:*** воспитывать чувство гордости и патриотизма у юного гражданина; воспитывать такие личностные качества как доброта, честность, взаимопомощь; воспитывать у детей культуру труда и этику общения; воспитывать бережное отношение к природе, родному краю.

Программа для учащихся 5-6 классов рассчитана на один год в объёме 34 часа (по одному часу в неделю).

**Актуальность.** Школа – отражение жизни общества. В современных условиях развития нашего общества, когда глубокие перемены, происходившие в жизни России, повлияли на ослабление внимания к патриотическому воспитанию подрастающего поколения, в общественном сознании получили широкое распространение равнодушие, эгоизм, цинизм, немотивированная агрессивность, неуважительное отношение к государству. В результате понижается нравственно-культурный уровень, возникает социальная пассивность, безразличие.

Выход из этого положения возможен в формировании активной жизненной позиции молодого поколения, приобщении его к нравственным, духовным ценностям, возрождении традиций нашей страны. Нет универсального рецепта, как воспитать ребенка, чтобы он стал настоящим гражданином, любящим свою Родину, в которой он родился, где корни его народа, который будет ею гордиться. Таким образом, воспитание патриотизма является одной из основных задач воспитания.

Осуществление патриотического воспитания предполагает использование различных методических средств. Одним из таких средств является деятельность краеведческого кружка «Мой родной край». Сегодня ни один предмет в учебном плане не обходится без включения в него элементов краеведения. И это понятно, так как каждому человеку, каждому народу надо осознать себя и своё место в мире природы, среди других людей, среди других народов, а это невозможно без знания истории, без изучения культуры, обычаев и традиций своей Родины. Каждый человек связан с прошлым, настоящим и будущим своей страны, поэтому необходимо, чтобы дети хорошо знали свои истоки, историю, культуру своего края.

Предлагаемая программа кружка выполняет познавательную, развивающую, практико-ориентирующую и развлекательную функции, отвечая особенностям того возраста, для которого она предназначена (младшим школьникам), призвана помочь увязать краеведческие знания, полученные учащимися на уроках, с умением использовать их в реальной ситуации.

Кружковая работа входит в систему дополнительного образования. Сюда входят занятия с кружковцами, подготовка команды к предметным олимпиадам, интеллектуальным марафонам, предметным турнирам, групповая работа, подготовка к научным чтениям, исследовательская работа

Данная программа предусматривает изучение материала на английском языке через родной (татарский) язык. Изучая английский язык через родной (татарский язык) мы предполагаем заложение прочных основ всех видов речевой деятельности на элементарном коммуникативном уровне. Опора на родной язык предусматривается в организации процесса формирования произносительных, графических, орфографических, лексических и грамматических навыков. Курс внеурочного направления предусматривает осмысление усваиваемого материала: показа общности в английском и татарском языках, использование перенос и интерференции в обучении лексике и грамматике. Использование сравнительного изучения английского через родной (татарский) язык позволит сформировать у учащихся

приемы самостоятельной работы с языком, которые дадут им возможность расширять свой словарь, совершенствовать речевые умения.

**Ожидаемые образовательные результаты.**

-Оценивать жизненные ситуации (поступки людей) с точки зрения общепринятых норм и ценностей.

- В предложенных ситуациях, опираясь на общие для всех простые правила поведения, делать выбор, какой поступок совершить.

-Определять цель деятельности на занятии с помощью учителя и самостоятельно.

- Высказывать свою версию, пытаться предлагать способ её проверки

- Определять успешность выполнения своего задания в диалоге с учителем.

- Ориентироваться в своей системе знаний: понимать, что нужна дополнительная информация (знания) для решения учебной задачи

- Делать предварительный отбор источников информации для решения учебной задачи.

- Добывать новые знания: находить необходимую информацию

- Добывать новые знания: извлекать информацию, представленную в разных формах (текст, таблица, схема, иллюстрация и др.).

-Перерабатывать полученную информацию: наблюдать и делать самостоятельные выводы.

-Донести свою позицию до других: оформлять свою мысль в устной и письменной речи (на уровне одного предложения или небольшого текста).

-Слушать и понимать речь других.

-Вступать в беседу на занятии и в жизни.

В итоге учащиеся смогут использовать иностранный язык как средство общения, средство приема и передачи информации об окружающей действительности в естественных условиях социальной жизни и смогут адаптироваться к изменяющимся условиям жизни.

**Тематическое планирование**

| Название разделов | Всего часов | Теоретические занятия | Практические занятия |
|---|---|---|---|
| Краеведение | 1 | 1 | - |
| Моя семья | 4 | 3 | 1 |
| Мой край на карте Родины-Большой Кукмор | 8 | 5 | 3 |
| Звучит гордо - город Кукмор | 5 | 3 | 2 |
| Природа моего края | 5 | 4 | 1 |
| Культура и быт родного края | 5 | 4 | 1 |
| Музей-хранилище истории | 4 | 2 | 2 |
| Итоговые занятия | 2 | 1 | 1 |
| Итого | 34 | 23 | 11 |

**Содержание курса внеурочной деятельности**

**1.Введение (1 час)**

Тема 1.Краеведение- наука о родном крае.(1ч)

**2.Моя семья (4 часа)**

*Тема 1.*Я и моё имя.(1 ч)

*Тема 2.*Корни моей семьи. Моя родословная.(1ч)
*Тема 3.* Наша дружная семья. Традиции моей семьи. (1ч)
*Тема 4.*Творческий конкурс «Старая фотография рассказала…» (1ч)

**3.Мой край на карте Родины – Большой Кукмор (8 часа)**

*Тема 1.*Вот моя деревня - вот мой дом родной. (1ч)
*Тема 2.*Моя улица. (1ч)
*Тема 3.*О чем говорят топонимические названия в селе.(5ч)
*Тема 4.* Знаменитости моего села.(1ч)

**4.Звучит гордо - город Кукмор (5 часов)**

*Тема 1.*Город, в котором я живу.(2ч)
*Тема 2.* Экскурсия в городской краеведческий музей. Знакомство историей возникновения родного города. (1ч)
*Тема 3.*Люди, прославившие город (1ч)
*Тема 4.* Конференция «Достопримечательности родного города» (1ч)

**5.Природа моего края (5 часов)**

Тема 1.Климат. Сезонные изменения погоды. (1ч)
Тема 2.Растительный мир Татарстана. Животный мир Татарстана. Птицы родного края.(1ч)
Тема 4. Охранять природу – значит охранять Родину.(1ч)
Тема 5. Конференция, творческие работы учащихся на тему «Мой край родной – мой Татарстан». (1ч)

**6.Культура и быт родного края (5 часов)**

*Тема 1.*Народы родного края.
*Тема 2.*Народные обычаи, обряды, традиции. Устное народное творчество (пословицы, поговорки).
*Тема 3.*Народные промыслы Кукморского народа.
*Тема 4.*Творческий конкурс.

**7.Музей - хранилище истории. (4 часа)**

*Тема 1.*Роль музея в жизни человека. (2ч)
*Тема 2.*Основные социальные функции музеев.
*Тема 3.*Посещение музеев.

**Итоговые занятия (2 часа)**

*Литература*

1. Журнал «Мир бизнеса» № 2, 2007год
2. Завьялов М.К.. Татарский костюм. – Казань, изд. «Заман», 1996 г.
3. Нургалиева Ч.Р. научно-исследовательская работа «Пословицы и поговорки в сравнении с татарским языком»
4. Яруллина Л.А. «Открой для себя Татарстан», Казань,2004

**Интернет ресурсы:**
http://redbook-tatarstan.ru/

## ҖЫЛЫ СҮЗ – ҖАН АЗЫГЫ

*Нуриева Миләүшә Мөхәррәм кызы,*
*МБГБУ "Ядегәр урта гомумибелем бирү мәктәбе"*
*Югары Шәмәрдән авылындагы филиалы ,*
*Кукмара районы*

**Фәне:** әдәби уку
**Сыйныф:** 4 нче
**Тема:** Җылы сүз – җан азыгы
**Максат:**

- Г. Валиеваның “Карт алаша колагы” хикәясе белән таныштыру;
- укучыларның әсәрнең жанрын, төп идеясен, проблемасын дөрес табуларына ирешү; логик һәм иҗади уйлау-фикерләү сәләтләрен үстерү, уку күнекмәләрен камилләштерү;
- балаларда бердәмлек, дуслык, туганлык хисләре, әдәплелек тәрбияләү.

**Дәреслек УМК:** Г.М.Сафиуллина, Ф.Ф.Хәсәнова, Ә.Г.Мөхәммәтҗанова. Әдәби уку. Татар телендә башлангыч гомуми белем бирү мәктәбенең 4нче сыйныфы өчен дәреслек. Казан: “Мәгариф-Вакыт”, 2014, 3 нче кисәк 93-97 нче битләр.

**Кулланылган әдәбият:** 1.Сафиуллина. Г.М., Хәсәнова Ф.Ф., Мөхәммәтҗанова Ә.Г. Әдәби уку. Туган телдә (татар телендә) башлангыч гомуми белем бирү мәктәбенең 4нче сыйныфында эшләүче укытучылар өчен методик әсбап. Казан: “Мәгариф-Вакыт”, 2012.

2. Әдипләребез. Биобиблиографик белешмәлек. Казан, Татарстан китап нәшрияты, 2009

**Җиһазлау:** компьютер, проектор, экран, үзбәя өчен карта, тест;

**Дәрес төре:** яңа белем-күнекмәләр үзләштерү.

**Тип:** катнаш дәрес

**Көтелгән нәтиҗәләр**

***Танып-белү УУГ:(предметные УУД)***

- язучы, шагыйрь Гөлназ Валиеваны тану, аның әсәрләрен укуга теләк уяту;
- Г. Валиеваның “Карт алаша колагы” хикәясен уку

***Шәхси УУГ:(личностныеУУД)***

- татар халкының тарихи үткәне белән кызыксыну булдыру;
- шәфкатьлелек, мәрхәмәтлелек, әхлаклылык сыйфатларын үстерү;
- авыл тарихын өйрәнүгә кызыксыну булдыру.

***Предметара УУГ(метапредметные УУД)***

**<u>Көйләгеч (регулятив) УУГ</u>**:

- укучылар белгән, әлегә кадәр белмәгән күнекмәләрне үзара бәйләү;
- максатларның эзлеклелеген билгеләү, план төзү.

**<u>Танып белү УУГ:</u>**

- табигать бербөтенлеген, бәйләнешләрен белү, танып-белү максатын билгеләү;
- әсәрдәге күтәрелгән проблеманы чишү, сорауларга тулы җавап бирә белү,предметара бәйләнешләрне кулланып, кирәкле информация туплау;
- язучы тормыш юлы турында белемнәрен арттыру, шәхси батырлык үрнәген аңлауга ирешү, эзләнүле һәм иҗади характердагы проблемаларны чишү юлларын мөстәкыйль таба белү.

**<u>Коммуникатив УУГ:</u>**

- укытучының, сыйныфташларның сорауларына җавап бирү;
- сөйләм этикеты нормаларын үтәү: исәнләшә, саубуллаша, рәхмәт белдерә белү;
- башкаларның сөйләмен тыңлый һәм аңлый белү;
- укыту процессында катнашу, иптәшеңнең үз-үзен тотышы белән идарә итү;
- үз фикерләрен әйтә белү;

**Предметара бәйләнеш:** әдәби уку, әйләнә-тирә дөнья, рус теле, музыка

**Дәрес барышы**

**I.Ориентлашу- мотивлаштыру**

1.Уңай халәт тудыру

Максат: укучыларның дәреснең үзләре өчен кирәк булуын аңлап, эшчәнлек башлаулары

1.- Хәерле көн, укучылар! Укучылар бер –берсен кул бирешеп сәламлиләр

- Хәерле көн, укытучым!
- Хәерле көн, сыйныфташым!
- Хәерле көн, кунаклар!
- Хәерле көн, алсу таңнарга!
- Хәерле көн, зифа талларга!
- Хәерле көн, зәңгәр суларга!

- Хәерле көн, назлы җилемә!
- Хәерле көн, туган җиремә!

Мин сезгә бүгенге дәрестә тел ачкычы, аң-зиһен, акыллы, матур җаваплар бирүегезне, яхшы кәеф телим

2.Белемнәрне актуальләштерү

Максат: алдагы дәрестә алган белемнәрне искә төшерү. Өй эшен тикшерү

2.-Узган дәрестә без А. Алишның "Сертотмас үрдәк" әкият-пьесасы белән таныштык. Хәзер алган белемнәрне искә төшереп китәбез.

-Сертотмас үрдәкнең уңай һәм тискәре якларын язабыз (сингапур алымы буенча) Үзбәя бирү

5 балл – уңай, тискәре яклар барысы да
4 балл – 4 уңай яки тискәре як язылган
3 балл - 3 уңай яки тискәре як язылган
2 балл - 2 уңай яки тискәре як язылган
1 балл – 1 уңай яки тискәре як язылган

-Хәзер, укучылар, әкият –пьеса буенча алган белемнәрне барлап, тест чишәрбез.

1. Әкият-пьесаның авторы кем?
а) Г.Тукай
ә) А.Алиш
б) М.Җәлил

2. "Сертотмас үрдәк"нең төп герое кем?
а) төлке
ә) үрдәк
б) хуҗа белән эт

3.Сертотмас үрдәкне нәрсәгә җибәрәләр?
а) хуҗаны эзләргә
ә) этне эзләргә
б) хуҗа белән этне эзләргә

4.Ни өчен йорт хайваннары хуҗаны эзләргә сертотмасны җибәрәләр?
а) син очасың, син йөзәсең, син йөгерәсең
ә) син очасың, син йөзәсең, син тиз йөрисең
б) син йөзәсең, син йөгерәсең, син тиз йөрисең

5.Сертотмас белән нәрсә була?
а) ул өенә кайта
ә) ул бүредән кача
б) төлке Сертотмасны ботарлап балаларына бирә

Үзбәя
5балл – 5 сорауга дөрес җавап
4балл – 4 сорауга дөрес җавап
3балл – 3 сорауга дөрес җавап
2балл - 2 сорауга дөрес җавап
1 балл – 1 сорауга дөрес җавап

3.Уку мәсьәләсе кую

Максат: укучыларның дәрес темасын үзләре формалаштыра алу

**3**.Укучы һәм укытучы арасында әңгәмә

1. -укучылар бу әкият-пьесада төп геройлар нәрсәләр? (хайваннар)
- хайваннар ничә төргә бүленә? Нindиләр? ( ике төргә, йорт һәм кыргый хайваннар)
- Хайваннар ни өчен кирәк? ( сакчы, эшче, ......)

2.- Укучылар, хайваннар турында шагыйрьләребез бик күп шигырьләр, язучыларыбыз хикәя һәм әкиятләр язганнар, композиторларыбыз көйләр язып күп кенә җырлар туган. Шулай ук рәссамнарыбыз рәсемгә дә төшергәннәр.

**II. Уку мәсьәләсен адымлап (өлешләп) чишү**

1.Уку мәсьәләсен чишү

Максат: уку күнекмәләрен үстерү өстендә эшләүне формалаштыру;

таныш булмаган сүзләрнең мәгънәсен истә калдыру

1.-Мин сезгә бер язма тыңлатам игътибар белән тыңлагыз әле, нәрсә тавышын ишетерсез микән.(атлар).

-Әйе укучылар бу атларның тояк һәм кешнәү тавышлары иде. Атлар турында нәрсә әйтә аласыз?

- Әйе, укучылар, атлар халкыбызның тормыш-көнкүрешендә гаять мөһим урын тоткан. Ат – иң кадерле хайван: ашатучы һәм җылытучы, крестьян хезмәтен бик күпкә җиңеләйтүче. Сабан эшләре беткәч үткәрелә торган бәйрәмнәр – Сабантуй күрке дә ул, Бөек Ватан сугышы елларында батыр сугышчыларның көрәштәше, тыл батырларының эшче көче дә, транспорт чарасы да.

-Мин сезгә атлар турында кызыклы мәгълүматлар җиткерәм.

- Ат якыннан яхшы күрә: хәтта кешенең ым, ишарәсен тоя ала. Әмма ерактан начар күрә.
- Җир шарында бу хайванны иң кыска сүз белән атап йөртүчеләр - төрки халык, татарлар. Без аны «Ат» дибез. Иң озыны Көньяк Америка индеецлары телендә **«Оквилаупаракламарукоаллунакланата».**
- Ат төшне төсле итеп күрә.
- Ат 60 км/сәг тизлек белән чаба һәм 2,5 метр биеклеккә сикерә ала.
- Ат күз, борын, ирен, ияк, колак тирәсендә урнашкан озын төкләре (антенналары) ярдәмендә сизә.
- Атның иң курыккан җан иясе - умарта корты.
- Ат - нечкә күңелле.

(дәреснең проблемасы)

- Укучылар, сезнең атлар турында берәр әсәр укыганыгыз бармы?(Г.Ибраһимов әсәрләрендә дә ат образлары еш очрый)

-Ә бәлки мультфильмнар караганыгыз бардыр?

-Без бүген дәрестә, шундый яхшы җан иясе, кешенең дусты, ярдәмчесе булган хайван – ат турында язылган хикәя белән танышырбыз. Г.Вәлиеваның “Карт алаша колагы” әсәре .

2. Белемнәрне ныгыту.

Максат: ишетеп,күреп тану күнекмәләрен, бәйләнешле сөйләм телен үстерү

2. – укучылар кемнәр Гөлназ Вәлиева турында беләә? Нинди әсәрләрен укыганыгыз бар?

- Бүген безне иптәшләрегез Гөлназ апагыз Вәлиева белән таныштырырлар.

Г. Валиеваның тормышы һәм иҗаты белән танышу.

Гөлназ Мөдәррис кызы Вәлиева 1983 нче елның 25нче августында Казанда язучы Мөдәррис Вәлиев гаиләсендә дөньяга килә. Сабый чагыннан ук гаиләдә милли тәрбия алып. Шулай да, рус мәктәбендә укыганлыктан, тәүге әдәби тәҗрибәләрен ул рус телендә яза.

1998 нче елдан Гөлназ татар яшьләренең «Сәләт» иҗтимагый оешмасы эшләренә якыннан катнаша. «Сәләт» мохите, иҗатка сәләтле татар яшьләре белән аралашу аның иҗат омтылышларына уңай йогынты ясый. Ул татарча язылган шигырьләре, хикәяләре, әкиятләре белән «Сабантуй», «Шәһри Казан», «Ватаным Татарстан» газеталары, «Казан утлары», «Ялкын», «Идел» журналлары битләрендә күренә башлый.

Гөлназ 2000 нче елда Казандагы 70 нче урта мәктәпне тәмамлап, берьюлы ике югары уку йортына укырга керә Шул ук елда аның «Милли китап» нәшриятында шигырьләре һәм хикәяләре тупланган «Тылсым» исемле китабы дөнья күрә. «Тылсым» республика күләмендә үткәрелә торган «Ел китабы» бәйгесендә кызыксындыру дипломына лаек була.

Яшь каләм тибрәтүченең әдәби язмалары 2001нче елда «Мәгариф» нәшрияты бастырып чыгарган «Җәйнең җиде төсе» дигән җыентыгына кертелә.

Аның 2005нче елда Татарстан китап нәшриятында «Күңел күзе» дип аталган икенче китабы басылып чыга. Г.Вәлиева — 2002 нче елдан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы.

- Менә кем икән ул Г.Вәлиева.

3. Белемнәрне гомумиләштерү.

Максат: алган белем һәм күнекмәләрне ныгыту һәм гомумиләштерү

3. - Ә хәзер Г. Вәлиеваның "Карт алаша колагы" хикәясе белән танышуга күчик

- сүзлек өстендә эш

Җисем – әйбер(предмет)

Алаша – ат (трудяга лошадь)

Ат ялы – атның муенындагы озын, куе йон (лошадиная грива)

Бахбай – ат турында иркәләп әйтү ( ласковое название лошади)

Колакка киртләп кую – онытылмаслык итеп истә калдыру (зарубить себе на носу)

Җен ачулары чыгу – бик нык ачу чыгу( взбеситься, прийти в ярость).

Ат җене кагылу – атны карап, тәрбияләп, ат белән йөреп, аның тирәсендә бик күп вакыт уздыра торган ат яратучы кешегә карата әйтелә ( у него страсть к лошадям)

Бия – ат (кобыла, кобылица)

- Әйдәгез, хәзер хикәяне чылбыр рәвешендә укып чыгабыз

( укучылар укып чыгалар.)

- Менә хикәяне укып чыктык. Сез хикәя турында ни әйтерсез? Сездә нинди тәэсирлар калдырды ул?

- Хикәядә ничә төрле вакыйга турында сөйләнелә?

- Малайның атка карашында сез начарлык күрәсезме?

- Бу малай турында нәрсә әйтә аласыз?

- Син нинди кушаматлы атлар турында беләсең?

- Бу әсәр нәрсә турында? (ат) Автор ат образы буенча безне нәрсәгә өйрәтә? ( усаллыкка яхшылык белән җавап бирергә)

- Димәк, һәрвакытта да яхшылык җиңеп чыга

4.-Укучылар, сезнең алдыгызда конвертлар бар. Ул конвертларда рәсемнәр. Хикәянең эчтәлеге буенча рәсемнәрне эзлекле рәвештә ябыштырабыз.

- Нәтиҗә ясыйбыз, димәк беренче (икенче, өченче) нинди вакыйга сурәтләнә?

Үзбәя

5 балл- барлык этаплары да дөрес

4 балл - 1 хата

3 балл – 2 хата

2 балл – 3 хата

1 балл – 3тән күп хата

**III. Рефлексия, бәяләү**

1. Йомгаклау рефлексиясе

**Максат:** дәрестә башкарган эшләргә нәтиҗә ясау

- дәрес сезнең өчен файдалы булдымы?

- нинди өстәмә яңалыклар белдек?

- үзеңә дәрестә катнашуыңа нинди билге куярсың?

- әгәр дәрес ошаган булса ат рәсемен аласыз, аңлашылмаса, минем, иптәшләрегезнең фикерләре белән килешмәсәгез ат рәсемен алмагыз.. Үзбәя

2. Өй эше

**Максат:** укучыларның шәхси мөмкинлекләрен күздә тотып өй эшен өч дәрәҗәдә бирү

Өй эше:

- дәреслекнең 97 нче битендәге, үзегезгә ошаган 3-4 мәкальне ятларга; мәгънәсен аңлатырга;

- схема буенча эчтәлек сөйләргә;

- атлар турында хикәя язып килергә

3. Дәрескә гомуми бәя кую.

**Максат:** укучыларның яңа теманы үзләштерү буенча фикерләрен белү
Бәяләү нормасы:
13 - 15 балл булса “5”ле билгесе куела
10 - 12 балл булса “4”ле билгесе куела
7 - 9 балл булса “3”ле билгесе куела

## “БАРСЫН ДА БЕЛЕРГӘ ТЕЛИМ” ДӘРЕСТӘН ТЫШ ЭШЧӘНЛЕК ПРОГРАММАСЫ

*Рафикова Фирүзә Габделбәр кызы,*
*Мамадыш муниципаль районы*
*“Югары Ушмы төп белем мәктәбе”нең*
*башлангыч класс укытучысы*

Дәрестән тыш эшчәнлекнең гомуми интеллектуаль юнәлеше укучының танып белү һәм иҗади активлыгын арттырырга, шәхси сыйфатларын яхшыртырга мөмкинлек бирә. Төрле төрдәге ярышлар, логик фикерләүне үстерүче уеннар, кичәләр балаларның интеллектуаль үсешенә: хәтерен, игътибарлылыгын, уйлау һәм үзләштерү сәләтен үстерүгә этәргеч бирә,физик, акыл үсешенә һәм психикасына уңай йогынты ясый.

Тормыш таләбе бездән иртәге көн кешесенең үзенә юл сала алучы,мөстәкыйль карар кабул итүче һәм аны үти алучы итеп тәрбияләүне сорый. Шуңа күрә дәрестән тыш эшчәнлек вакытындаукучыга кыенлыкны табарга, аның сәбәпләрен ачыкларга, үз алдына максат куярга, үз эшен планлаштырырга, үзконтроль ясарга һәм үзбәя куярга өйрәтергә тиешбез.

Башлангыч сыйныфларда әйләнә-тирәне мөстәкыйль танып белү, аңа карата кызыксыну уяту, танып-белү активлыгын һәм инициативаны үстерүнең төп шарты буларак, үстерелешле укыту мөхите тудыру зарур.Программа яшь үзенчәлекләрен исәпкә алып җиңелдән катлаулана бару тәртибендә төзелде.

Кече яшьтәге мәктәп балаларына үз-үзен тикшерү өчен шарт тудыру мөһим. Бу аңа үзенең мөмкинлегенә төшенергә, уй-фикерләрен, эш-гамәлләрен читтән күзәтеп бәяләргә, куйган максаты белән эшенең нәтиҗәсен чагыштырып карарга ярдәм итә. Әлеге дәрестән тыш эшчәнлек материаллары тулысынча бу максатларга игътибар итеп төзелде.

**Максаты:**
- укучыларның интеллектуаль сәләтләрен ачу, үстерү.

**Бурычлары:**
- дәрестән тыш эшчәнлек ярдәмендә укучыларда белем алуга омтылуны тәрбияләү.
- укучыларның иҗади эзләнүчәнлеген булдыру.
- танып-белү эшчәнлеген, иҗади фикерләү сәләтен камилләштерү;
-үз мөнәсәбәтеңне белдереп сөйләргә, фикерне исбатларга, нәтиҗәләр чыгарырга өйрәтү;
- укучыларда ижат итү омтылышы уяту.

Программа башлангыч сыйныфларның 1-4 класслары өчен атнага 1 сәгать исәбеннән дүрт елга төзелде.

**Укучыларның белем, күнекмәләренә төп таләпләр:**
Ел ахырында укучылар белергә тиеш:
-төрле мәгълүмат белән эшләргә өйрәнергә;
-тикшеренү эшләре алып барырга;
- туган як, татар халкы мәдәнияты, традицияләре турында күбрәк мәгълүмат тупларга;
- карта белән эшли белергә;
- үсемлек, хайваннарны күзәтергә; кыргый һәм игүле үсемлекләрне, куакларны, агачларны аера белергә;
- табигатьтә мөстәкыйль күзәтүләр үткәрә белергә;

- сүзлекләр белән эшли белергә;
- табышмаклар,ребуслар,башваткычлар чишә белергә;
- үзеңнең сәламәтлегеңне, шәхси куркынычсызлык кагыйдәләрен саклый белергә;

**Предметны укыту программасына нигезләнеп үзләштерү нәтиҗәләре**

Шәхескә юнәлтелгән УУГ (универсаль уку гамәлләре)
- үз эшчәнлегенең нәтиҗәләрен яхшыртуга ихтыяҗ формалаштыру;
- үз мөмкинлекләреңне бәяләү, тормыш тәҗрибәсен куллану;
- түгәрәктә үзенең белем һәм күнекмәләрен куллану;
- үз фикереңне әйтә белү;
- иҗади эшчәнлеккә омтылыш булдыру;

**Таныпбелү универсальукугамәлләре**

- Үзенә кирәкле информацияне таба белү; анализлый һәм информацияне бәяли белү;
- логик фикерләү чылбырын төзү;
- тәкъдим ителгән план ярдәмендә предмет, күренешләрне сурәтләү;
- тәҗрибә кулану аша нәтиҗә чыгару;

**Регулятив (көйләгеч) универсаль уку гамәлләре**

- белгәнне һәм белмәгәнне аера белү;
- үз эшчәнлегеңне контрольгә алу, рәсемнәр ярдәмендә биремне үтәүнең дөреслеген тикшерү;
- эшләнәчәк эшкә мөстәкыйль максат куя белү;
- үз-үзеңне ихтыяр буенча көйләү;
- бәяләү нәтиҗәсен шартлы символик формада чагылдыру;
- -түгәрәктә өйрәнелгән материалның фәнне өйрәнүдәге, тормыштагы әһәмиятен ачыклау;
- -үтәлгән эшнең сыйфатын һәм дәрәҗәсен билгеләү, уңышлылыгына бәя бирү;. Уңышсызлыкларның сәбәбен аңлый һәм ул ситуациядән чыгу юлларын таба белү.

**Коммуникатив универсаль уку гамәлләре**

- Тыңлаучыларга аңлаешлы сөйләм төзү;
- күзаллау, фаразлау; логик фикерйөртүосталыгы; күршең белән хезмәттәшлек итү; фикерләү сәләтен үстерү, карарлар кабул итү һәм анны тормышка ашыру; үз фикереңне тулы, төгәл һәм ачык, аңлаешлы итеп әйтү, анны яклау;
- җитмәгән мәгълүматны башкалардан сорашып белү; иптәшеңнең үз-үзен тотышы белән идарә итү.

**Программаны тормышка ашыру шартлары:**

- Каралган барлык теоретик материалны өйрәнү һәм барлык практик шөгыльне үтәү.
- Һәр балага индивидуаль якын килү, һәр балага шәхес итеп карау.
- Барлык дидактик материалдан һәм информацион - коммуникатив технология чараларыннан файдалану.

**Эшчәнлекнең форма һәм методлары:**

- укучылар белән әңгәмәләр;
- табигатьтә күзәтүләр, экскурсияләр
- викториналар, конкурс, төрле ярышлар
- анкеталар; тестлар;
- иҗади биремнәр үтәү: альбомга материаллар туплау, сочинение, рәсем, әвәләү, төрле темаларга зур булмаган телдән журнал әзерләү, газета чыгару
- рәсемнән күргәзмә оештыру

**Эшчәнлекнең нәтиҗәсе:**

- Укучыларны дәрестән тыш эшчәнлеккә тартып, аларның активлыгын үстерү.
- Мәктәп, район, республика, Россия күләмендә оештырыла торган интелектуаль уен, конкурсларда актив катнашу.
- Балалар арасында бердәмлек, коллективта үз – үзеңне дөрес тоту сыйфатлары булдыру

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | Кереш дәрес | Программа эчтәлеге,максаты,бурычлар белән таныштыру. | Гади интеллектуаль уеннар. | | |
| | Үз-үзеңне беләсеңме? | Кеше гәүдәсенең төзелеше белән таныштыру. | Үз гәүдәңдә соралган әгъзаны күрсәтү | | |
| | Безнең адрес. | Авыл, район, республика, ил төшенчәсен кыскача аңлату. | Үз адресыбызны төзү | | |
| | Геометрик фигуралар | Геометрик фигураларның төсе, формалары, күләмнәрен аеру буенча логик уеннар | Кәгазьдән фигураалар кисү | | |
| | Игътибарлылыкны үстерү уеннары | Шырпылар ярдәмендә уеннарның сере нәрсәдә-әңгәмә | Шырпылар ярдәмендә логик уеннар | | |
| | Күзәтүчәнлекне үстерү уеннары | Таякчыклар ярдәмендә уен төрләрен өйрәтү | Таякчыклар ярдәмендә уеннар | | |
| | Бер сызык белән | Карандашны кәгазьдән алмыйча бирелгән фигураларны ясау серен аңлату | Бер сызык белән фигураларны ясау | | |
| | Канатлы дусларыбыз | Кошлар турында кыскача мәглъүматлар бирү. | Пластилиннан кош әвәләү | | |
| | Сүзләр илендә | Әйләнмә сүзләр төзү серләре | Әйләнмә сүзләр төзү | | |
| 0 | Адашкан авазлар | Авазларның нинди сүздә алашканлыгыын табу | Пластилиннан хәрефләр әвәләү | | |
| 1 | Урманга сәяхәт | Агач,куак,үсемлекләрне төп билгеләрен ачыклау | Яфраклары буенча агачларны аеру | | |
| 2 | Җәнлекләр дөньясы | Кайсы җәнлек кайда яшәвен ачыклау | Пластилиннан җәнлекләр әвәләү | | |
| 3 | Йорт хайваннары | “Парын тап!”логик фикер йөртү өчен уеннар. | Хайваннар турында табышмаклар чишү | | |
| 4 | Магик квадратлар | “Серле квадратларның сере нәрсәдә” -әңгәмә | Гади магик квадратларны чишү | | |
| 5 | Ашык, тик ялгышма! | Телдән исәпләү алымнарын өйрәтү | Телдән исәпләү күнегүләре чишү | | |
| 6 | Башта кайсы? | Рәсемнәрдәге логик бәйләнешне аңлату | Карточкаларны тәртип белән урнаштыру | | |
| 7 | Табышмаклар илендә | Табышмак чишү серләрен аңлату | Табышмак чишү | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 8 | Шашка уены | “Шашка уены кайчан килеп чыккан”- әңгәмә уздыру | Уен тәртипләрен өйрәтү | | |
| 9 | Табын серләре | Этикет кагыйдәләре белән таныштыру | Сюжетлы уен | | |
| 0 | 10 аерманы тап | Төп аермаларны таба,аера белергә өйрәтү | Рәсемнәр белән уеннар | | |
| 1-22 | Ребуслар | Ребуслар төзү,чишү юлларын аңлату | Рәсемле ребуслар чишү | | |
| 3 | Пыялакайчанбарлыккак илгән? | “Кешеләр пыяланы ничек тапканнар?”-әңгәмә | “Тәрәзәдәге бизәкләр” Рәсем ясау | | |
| 4 | Фикерләү сәләтен үстерүче уеннар “Кайсы артык?” уены | Артык предметны табу серләрен аңлату | Фикерләү сәләтен үстерүче уеннар | | |
| 5 | Нәрсә кайда яши? | Төрле хайваннарның кайда, ничек яшәүләрен ачыклау буенча әңгәмә | Картага хайван рәсемнәрен урнаштыру | | |
| 6 | Барсы да спорт турында | Спорт төрләрен ачыклап үтү | “Син кайсы төрне сайлар идең”темага рәсем | | |
| 7 | Витаминнар илендә | “Витамин нәрсәул?”презентация | Викторина сорауларына җавап бирү | | |
| 8 | Тап һәм әйт | Балаларны татар халык бизәкләре белән таныштыру, исемнәрен дөрес әйтә белү. | Бизәкләрнең исемнәрен дөрес әйтә белү. | | |
| 9 | Ни өчен яңгыр ява? | Яңгыр яву сәбәпләрен аңлату | Яңгыр белән бәйле такмаклар өйрәнү | | |
| 0 | Салават күпере төсләре | “Салават күпере”презентация карау | Салават күперенең рәсемен ясау | | |
| 1 | Туган авылым | Авыл урамнары,җәмәгать биналары турында әңгәмә | Авыл буйлап экскурсия | | |
| 2 | “Бер сүз белән әйт” | Укучыларга предмет рәсемнәре күрсәтелә, алар бер сүз белән әйтәләр | Иҗади сәләтне үстерүче уеннар уйнау | | |
| 3 | “Кем иң тапкыр?” | Интеллектуаль бәйге уздыру | Бәйгедә катнашу | | |

**2 класс**

| | Тема | Теоретик өлеш | Практик өлеш | И скәртмә | ата |
|---|---|---|---|---|---|
| | Кереш дәрес | Программа эчтәлеге,максаты,бурычлар белән таныштыру | Гади интеллектуаль уеннар. | | |
| | Безнең | Республика,ил,материк | Үз адресыбызны | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | адрес | лар,планета турында төшенчә бирү | төзү | | |
| | Үз-үзеңне беләсеңме? | Тою органнары белән таныштыру.Сәламәтлекне саклау кагыйдәләрен искәртү | Көндәлек режимны төзү | | |
| | Әдәбият иленә сәяхәт | Әдәби әсәрләрләрнең авторларын,әсәрнең ни өчен алай аталуын аңлату | Әдәби викторина | | |
| | Әкият шәһәрендә | Әкиятләрнең төрен,килеп чыгышын аңлату | Өзекләр буенча әкиятне тану,аларны чагыштыру,уртаклыкларын табу | | |
| | Сүзләр дөньясында | Сүздәге хәрефләрне үзгәртеп яңа сүзләр ясауның асылын аңлату | “Түгәрәк сүзләр”, “Сүзнең парын тап”уеннары | | |
| | Геометрик фигуралар | Геометрик фигураларның төсе,формалары,күләмнәре аеру буенча логик уеннар | Фигуралардан чеби,өй аппликацияләре ясау | | |
| | Урманга сәяхәт | Агач,куак,үсемлекләрне төп билгеләрен ачыклау | Билгеләре буенча үсемлекләрне тану | | |
| | Табигать күренешләре | Табигать күренешләре белән бәйле игътибарлылыкны үстерүче уеннар. | Танграммалар төзү | | |
| 0 | Кошлар | Кошлар тормышыннан кызыклы вагыйгалар белән таныштыру | Рәсем буенча кошларны тану | | |
| 1 | “Яңа сүз” | Бу уенда укытучы үзе төрле сүзне куллана ала. Алынган сүздән башка сүзләр төзергә кирәк. | Алынган сүздән башка сүзләр төзү | | |
| 2 | “Тылсымлы чылбыр” . | Һәр сүз алдан килгән сүзнең соңгы иҗегеннән башлана. | Логик уеннарда катнашу | | |
| 3 | “Хаталар Корольлегендә” | Киң таралган орфоргафик ялгышлар өстендә эш | Уен “ Сихерле алмагач”. Ситуацияләрне чишү күнегүләре | | |
| 4 | “Сүздән сүз килеп чыгу” | Бер хәрефне өстәп яисә алмаштырып яңа сүз ясау алымнарны аңлату | Иҗади сәләтне үстерүче уеннар уйнау | | |
| 5 | “Булсаң зирәк - әйт тизрәк” | Укытычы сүзләр әйтәргә укучылар аларны башкача әйтергә тиеш | Фикерләү сәләтен үстерүче уеннар | | |
| 6-17 | Ребуслар | Ребуслар төзү,чишү юлларын аңлату | Рәсемле ребуслар чишү | | |
| | Санлы | Гамәл тәртипләрен | Мисаллар дөрес | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 8 | бизәкләр | аңлату | булырлык итеп гамәл тамгаларын куярга | | |
| 9 | Барсы да спорт турында | Спорт төрләрен карап үтү.Командаларда кеше санын ачыклау | Рәсем буенча спорт төрләрен тану | | |
| 0 | Игътибар лылыкны үстерү уеннары | Шырпылар ярдәмендә уеннарның серен аңлату | Шырпылар ярдәмендә логик уеннар | | |
| 1 | Бер сызык белән | Карандашны кәгазьдән алмыйча бирелгән фигураларны ясау серен аңлату | Өй,аю рәсемнәрен ясау | | |
| 2 | Ашык ,тик ялгышма! | Телдән исәпләү күнегүләре чишү | Олимиада эшләре эшләү | | |
| 3-24 | Табышма клар илендә | Табышмак чишү серләрен аңлату | Табышмак чишү | | |
| 5 | Танграмм а | Танграмм аны уены белән таныштыру | Танграммалар төзү | | |
| 6 | Витаминн ар илендә | Витамин төрләре турында әңгәмә | “Витаминнар иленә” сәяхәт | | |
| 7 | Курчакла р кайчан барлыкка килгән? | Курчакларның барлыкка килү тарихын өйрәнү | “Яраткан уенчыгым”хикәя язарга | | |
| 8 | Атна көннәре | Атна көннәренең килеп чыгу тарихы белән таныштыру | Көннәр белән бәйле санамышлар өйрәнү | | |
| 9-30 | Шашка уены | “Шашка уены кайчан килеп чыккан?”- әңгәмә уздыру | Уен тәртипләрен өйрәтү | | |
| 1 | Баллыдан баллы | Конфетның барлыкка килү тарихы белән таныштыру | “Йолдызлы сәгать” уены | | |
| 2 | Туган авылым | Авыл чишмәләренең тарихы белән танышу | Яраткан чишмәнең рәсемен ясау | | |
| 3 | Районыбы зның атаклы шәхесләре | Районыбызның атаклы шәхесләре турында презентация | Блиц турнирсорауларынаҗа вап бирү | | |
| 4 | “Кем иң тапкыр?” | Интеллектуаль бәйге уздыру | Бәйгедә катнашу | | |

**3 класс**

| | Тема | Теоретик өлеш | Практик өлеш | Искәртмә | ата |
|---|---|---|---|---|---|
| | Кереш дәрес | Программа эчтәлеге,максаты,бурычлар белән таныштыру | Гади интеллектуаль уеннар. | | |
| | Безнең адрес | Дөнья | Карта белән | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | кисәкләре,материклар ы турында презентация | практик эш | | |
| | Үз-үзеңне беләсеңме? | “Төз гәүдә ни өчен кирәк?”- сәламәтлекне саклау кагыйдәләрен искәртү | Өстәл артында утыру кагыйдәләрен өйрәнү | | |
| | Әдәбият иленә сәяхәт | Әдәби әсәрләрләрнең авторларын,әсәр нең ни өчен алай аталуын аңлату | Әдәби викторина | | |
| | Әкият шәһәрендә | Әкиятләрнең төрен,килеп чыгышын аңлату | Өзекләр буенча экиятне тану,аларны чагыштыру,уртаклык ларын табу | | |
| | Мнемотаблицалар | Таблицалар белән эшләү тәртибен аңлату | “Гали белән Кәҗә” шигыре өстендә эш | | |
| | Ребуслар | Ребуслар төзү,чишү юлларын аңлату | Ребуслар чишү | | |
| | Танграмма | Танграмманы уены белән таныштыру | Танграммалар төзү | | |
| | Фразеологизмнар | Фразеологизмна рнар белән таныштыру | Фразеологизмна рнарның мәгънәләрен ачыклау | | |
| 0 | Метаграммалар | Метаграммалар чишүнең тәртибен аңлату | Метаграммалар, шаян табышмак-сораулар чишү | | |
| 1 | Ялгышлар иленә сәяхәт | Киң таралган орфоргафик ялгышлар өстендә эш | Сүзлек диктанты язу | | |
| 2 | Анаграммалар | Анаграммаларн ы чишү тәртибен аңлату | Анаграммалар,ә кият-табышмаклар чишү | | |
| 3 | Пыялакайчанбарл ыккакилгән? | Кешеләрпыялан ы ничек тапканнар? | “Тәрәзәдәге бизәкләр” рәсем ясау | | |
| 4 | Витаминнар илендә | “Витаминнар безгә нигә кирәк?”презентация | “Кайсы витаминны кайдан алырга ?” уен | | |
| 5 | Кыш бабай һәм Яңа ел | Кыш бабай һәм Яңа ел бәйрәменең тарихы, йолалары турында презентация | Кыш бабайга хат язу | | |
| 6 | Транспорт | Транспортның килеп чыгу тарихы белән таныштыру | “Хыялдагы машинам” рәсем ясау | | |
| | Почта ничек йөри? | Почтаның | Туганга хат язу | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 7 | | тарихы ,эшләү рәвеше белән таныштыру | | | |
| 8 | Барсы да спорт турында | Районыбызның атаклы спортчылары белән таныштыру | “Спортчыдан интервью алабыз”уены | | |
| 9 | Игътибарлылыкны үстерү уеннары | Шырпылар ярдәмендә уеннарның сере нәрсәдә | Шырпылар ярдәмендә логик уеннар | | |
| 0 | Табышмаклар илендә | Табышмак чишү серләрен аңлату | Табышмак төзү, чишү | | |
| 1 | Акча берәмлекләре | Кайсы илдә нинди акча йөргүен ачыклау буенча әңгәмә | Блиц турнир уздыру | | |
| 2 | Ашык ,тик ялгышма! | Телдән исәпләү күнегүләре чишү | Олимиада эшләре эшләү | | |
| 3 | Иң беренче музыка кораллары | Музыка коралларының тарихы белән таныштыру | “Уен кораллары”-викторина сорауларына җавап бирү | | |
| 4-25 | Шашка уены | Шашка уены кайчан килеп чыккан әңгәмә уздыру | Уен тәртипләрен өйрәтү | | |
| 6 | Дөрес туклану серләре | Дөрес туклану серләре белән уртаклашу | “Син беләсеңме ?” туклану белән бәйле сораулар | | |
| 7 | Исәпләү күнекмәләрен үстерүгә уеннар | Уйлаган санны белү серләренә өйрәтү | Уйлаган санны белү | | |
| 8 | Урра!Цирк! | “Цирк кайчан барлыкка килгән?” әңгәмә | “Без циркта”аппликация ясау | | |
| 9 | Дендрарий | Дендрарий белән таныштыру. “Сочидагы дендрарий” презентация карау | Хыялдагы агач рәсемен ясау | | |
| 0 | Җир йөзендә ничә океан? | Океаннар белән таныштыру | Карта янында практик уен | | |
| 1 | Туган авылым | Авыл тарихы белән таныштыру | Элекке авыл урамнарының сызымын сызу | | |
| 2 | Районыбызның атаклы шәхесләре | Районыбызның атаклы шәхесләре турында презентация | Блиц турнирсорауларынаҗ авап бирү | | |
| 3 | Стенгазета чыгару | “Стенгазета нәрсә ул?”-әңгәмә | “Безнең түгәрәк” стенгазета чыгару | | |
| | “Кем иң тапкыр?” | Интеллектуаль | Бәйгедә | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 4 | | бәйге уздыру | катнашу | | |

**4 класс**

| | Тема | Теоретик өлеш | Практик өлеш | Ис кәртмә | ата |
|---|---|---|---|---|---|
| | Кереш дәрес | Программа эчтәлеге,максаты,бурычлар белән таныштыру | Гади интеллектуаль уеннар. | | |
| -2 | Безнең адрес | Кояш системасы турында презентация | Брейнг-рингта катнашу | | |
| | Үз-үзеңне беләсеңме? | “Йөрәк турында барсын да беләбезме?”–әңгәмә. Сәламәтлекне саклау кагыйдәләрен искәртү | Чыныгу кагыйдәләрен өйрәнү | | |
| | Әкият илендә | Әкиятләрнең төрен,килеп чыгышын аңлату | Өзекләр буенча әкиятне тану,аларны чагыштыру, уртаклыкларын табу | | |
| | Танграмма | Танграмманы уенының тарихы белән таныштыру | Танграмалар төзү | | |
| | Син беләсеңме? | Кайсы илдә нинди акча берәмлеге турында әңгәмә | Акча берәмлеген тану буенча уен | | |
| -9 | Ребуслар | Ребуслар төзү,чишү юлларын аңлату | Ребуслар чишү | | |
| 0-11 | Табышмаклар илендә | Табышмак чишү серләрен аңлату | Табышмак төзү,чишү | | |
| 2 | Велосипед кайчан барлыкка килгән? | “Велосипедның барлыкка килү тарихы”әңгәмә | Хыялдагы велосипедның рәсемен ясау | | |
| 3 | Урра!Цирк! | “Циркта нинди серләр яшеренгән? | “Без циркта!” кечкенә проект эше эшләү | | |
| 4 | Тимурчылар. | “Тимурчылар кемнәр алар?”-әңгәмә | “Тимур һәм аның командасы” хикәясеннән өзекләр уку | | |
| 5 | Кыш бабай һәм Яңа ел | “Кайсы илдә Яңа ел бәйрәмен ничек уздыралар?”-әңгәмә | Кыш бабайга хат язу | | |
| 6 | Витаминнар илендә | “Витаминнарны кайдан алырга?”әңгәмә | Витаминлы салат рецепларын өйрәнү | | |
| 7 | Сәгать суга доң-доң.. | Беренче сәгатьнең кайчан барлыкка килүен ачыклау | 22нче гасыр сәгатенең рәсемен ясау | | |
| 8 | Ашык ,тик ялгышма! | Телдән исәпләү күнегүләре чишү | Олимиада эшләре эшләү | | |
| | Фразеологи | Фразеологизмнар | Фразеологизмнар | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 9 | змнар | белән таныштыру | ның мәгънәләрен ачыклау | | |
| 0-21 | Һәр дәүләтнең үз башкаласы | Чит илләрнең башкалалары белән таныштыру | Блиц турнир уздыру | | |
| 2 | Олимпия уеннары | Олимпиадалар турында әңгәмә уздыру | Үзеңә ошаган олимпиада эмблемасын ясау | | |
| 3 | Игътибарлылыкны үстерү уеннары | Шырпылар ярдәмендә уеннарның серен ачыклау | Шырпылар ярдәмендә логик уеннар | | |
| 4 | Транспорт | Транспорт төрләре белән таныштыру | “Хыялдагы машинам” рәсем ясау | | |
| 5 | Акча берәмлекләре | Кайсы илдә нинди акча йөрүен ачыклау буенча әңгәмә | “Кем тизрәк әйтә” уены | | |
| 6 | Исәпләү күнекмәләрен үстерүгә уеннар | Уйлаган санны белү серләренә өйрәтү | Уйлаган санны белү буенча башваткычлар чишү | | |
| 7 | Барысы да кино турында... | Киноның тарихы турында әңгәмә | “Мульти-пультииленә” сәяхәт | | |
| 8 | Флаг | Флагның килеп чыгу тарихын өйрәнү | Мәктәпнең флагын уйлап табу | | |
| 9 | Фотография кайчан барлыкка килгән? | Фотография барлыкка килү тарихы белән таныштыру | Мәктәп музеенда фотоаппаратлар коллекциясе белән танышу | | |
| 0-31 | Шашка уены | “Шашка уены кайчан килеп чыккан” әңгәмә уздыру | Уен тәртипләрен өйрәтү | | |
| 2 | Туган авылым | Авылның элеккеге җитәкчеләре,алдынгы эшчеләре турында әңгәмә | “Син авылны беләсеңме?”викторина сораулары | | |
| 3 | Районыбызның атаклы шәхесләре | Районыбызның атаклы шәхесләре турында презентация | Блиц турнирсорауларынаҗавап бирү | | |
| 4 | “Кем иң тапкыр?” | Интеллектуаль бәйге уздыру | Бәйгедә катнашу | | |

*Кулланылган әдәбият*


1.1-4 сыйныфлар өчен татар теленнән язма эшләр җыентыгы. Казан. 1997 ел.

2. С.Г.Вагыйзов “Кызыклы грамматика”. Казан 2002 ел.

3. В.А.Игнатьев “Башлангыч мәктәптә арифметикадан класстан тыш эшләр” Казан.1966 ел

4. И.Г.Сәгъдиев “Хикмәтле математика” Казан. 2004 ел.

# ШӘҖӘРӘДӘ ГАИЛӘМ ТАРИХЫ

*Сабирова Азалия Айдар кызы, 7 сыйныф*
*Фәнни җитәкче - Закирова Лилия Әхәт кызы, Арча муниципаль районының «Түбән Мәтәскә урта гомуми белем мәктәбе»*

**Кереш**

Безнең татар халкы бик борынгы заманнардан ук нәсел-ыру тарихын язуга зур әһәмиятен биргән. Шәҗәрә аркылы кешеләр ата-бабаларының дәвамчысы булуларына төшенгәннәр. Үз шәҗәрәңне белү, минем уйлавымча, кешедә туган илгә, җиргә, телгә мәхәббәт һәм сак караш тәрбияләргә, туганнарга, кардәш-ыруга, күрше-күләнгә хөрмәт һәм кайгыртучанлык күрсәтеп яшәргә кирәклеген кисәтеп тора.

Шәҗәрәләр безгә халкыбызның үткән юлын, чал тарихын сөйли. Үз шәҗәрәңне белү һәрберебезнең игелекле эше. Укытучыбыз мәктәп күләмендә шәҗәрәләр бәйгесе игълан иткәч, минем гаиләбезнең шәҗәрәсен матур итеп, тулы итеп төзү теләге уянды. Нәселеңне белү бервакытта да үз ***актуальлеген*** югалтмый.

Шәҗәрәләрне элек тә төзегәннәр. Казиле авылында Габитлар нәселе шәҗәрәсен Шәйхелисламов Ризван дигән кеше 1937 елда төзеп калдырган. Латин графикасында, бер китап тышлыгына язылган ул. Минем шәҗәрәмнең ***яңалыгы***булып аның заманча, компьютердан ясалуы һәм рамга урнаштырылып өйнең түренә эленүендә, ягъни, гаилә реликвиясенә әверелүендә.

***Эзләнү-тикшеренү эшемнең максаты:*** Үз гаиләмнең, Сабировлар гаиләсенең шәҗәрәсен өйрәнү.

***Фәнни тикшерү эшенең бурычлары*:**
- этием Айдар ягыннар туганнарны барлау;
-туганнарның кайда яшәве һәм һөнәрләре-кәсепләре турында мәгълүмат туплау;
-нәсел агачы – шәҗәрәне ясау.

***Методлар:,***
1. Әти-әнидән, әби-бабайлардан сорашу.
2. Өлешчә эзләнүле метод.
3. Интервью алу.

**Төп өлеш. Шәҗәрәдә гаиләм тарихы**

<u>*Кеше җирдә ни өчен яши?*</u>

Үзенең кыска гына гомере эчендә ул барысына да өлгерергә: барын да танырга, белергә, үзе эшләп карарга, сөенергә, шатланырга, кайгы – хәсрәтне җиңеп чыгарга һәм иң мөһиме – үзе турында киләчәк буынга якты истәлек калдырырга тырыша.”Әгәр үлгәч тә искә алсыннар дисәң, игелекле нәсел һәм эчтәлекле китап язып калдыр” – дигән борынгы акыл ияләре. “Илен белмәгән – игелексез, халкын белмәгән – холыксыз, нәселен белмәгән – нәсәпсез”, - дип халык юкка гына әйтмәгән. Адәм баласы үзенең 7 буынын бабасын белергә тиеш, дигән борынгылар. Шул вакытта гына кеше туган иленең, туган төбәгенең, туган йортының, үз халкының чыгышын белә.

Татарлар ислам динендә, мөселманнар. Дин һәр мөселман кешесенә җиде буын бабалары рухына дога укырга кирәклеген искәртә.

Олы кешеләр яшьләргә изге теләкләр теләгәндә: “Ата-анаңа игелекле бала бул!”- диләр. Ата-аналарын, милләтен, ата-бабаларының изге туфрагын хөрмәт итеп, кадерләп караганнар. Халкына файдалы гамәлләр кылып яшәгәннәрне халык та хөрмәт итә, “юньле, игелекле бала”, дип атый.

Шәҗәрә - нәсел агачы, бабаларыңның әллә ничә буынга кадәр исемнәрен, дөньядан үтү тәртипләрен белү дигән сүз. Татар телендә шәҗәрә сүзенең күп төрле синонимнары сакланган: шәҗәрә - тарих, нәсел шәҗәрәсе, нәсел җәдвәле, саҗәрә, шәҗәрә китабы, цәцрә, нәсел агачы, тарих, оруглык, тайрә һәм башкалар.

Нәсел тамырларын буыннан – буынга биреп, нәсел шәҗәрәсен төзү гадәти күренеш булган. Шәҗәрә аркылы халык ата – бабаларының дәвамчысы булуына төшенгән.

Мин Сабирова Азалия Түбән Мәтәскә авылында яшим, 6 класста укыйм. Үземнең нәсел-ыруым, туганнарым турында мәгълүмат туплап шәҗәрә төзергә булдым. Нәселебезне әтием Айдар ягыннан өйрәнә башладым.

*Нәсел башы Сабирҗан бабай һәм аның балалары*

Безгә билгеле булган нәсел башы бабабыз Мостафа исемле булган. Якынча ул XIX гасырның икенче чирегендә яшәгән. Аның нәселен дәвам итүче булып Сабирҗан бабай санала. Гаиләбез дә аның исеме белән ясалган фамилияне йөртә. Сабирҗанның дәвамчылары Нурислам, Фәрит һәм минем әтием Айдар. Алар барысы да Казиле авылында туып, шунда үскәннәр, тормыш иткәннәр.

Бабайларым бар да җир кешеләре булганнар: иген иккәннәр, терлек асраганнар. Игенчеләр-терлекчеләр династиясе дип атасаң дөрес булыр. Сабирҗан бабай урта хәлле крестьян булган. Аның биш баласы булганын белдем. Хаҗәр, Фагыйлә, Харис, Мәрьям, Нурислам. Мәрьям әби Иске Төрнәлегә Шакир бабайга кияүгә китә. Гомер буе авылда яшиләр. Ә аларның уллары Вәкил “Известия” колхозының танылган тракторчысы, II һәм III дәрәҗә Хезмәт даны ордены кавалеры. География фәне укытучым Дамирә апа һәм танылып килүче үзешчән шагыйрә Гәләра Шәрәпова Вәкил абый кызлары. Сабирҗан бабайның бер кызы Күпербаш авылына, икенчесе Кәче авылына кияүгә китәләр. Район тулы туганнарыбыз булу белән ничек куанмыйсың?!

Ә нәсел дәвамчысы улы Нурислам яшәгән чор зур үзгәрешләр чорына – колхозлашу чорына туры килә. 1929 нчы елда Казиле авылында колхозлашу башлана. Беренче оештыручысы Галимов Салих була. Колхозга кергән 12 колхозчының 6 сы ат һәм симәнәле, 6 сының аты да симәнәсе дә юк. Колхоз таркала. Озак та үтми, авыл халкы бер-бер атлы колхозга керә. Колхозга “Ударник” исеме бирелә. 1930 нчы елда колхоз төзелеп бетә. Иген чәчелә. Колхоз алты бригаданы эченә ала. 1167 га җире булган 180 хуҗалык. Менә шушы колхозның рәисе булып, Фәсхетдинов Нуретдин, Мөхәммәтҗанов Шакирләрне алыштырып эшли Сабиров Нурислам бабам. Нурислам бабай колхозны авыр сугыш елларында җитәкли. Мәктәп музеенда Казиле башлангыч мәктәбе тарихы бар. Бу истәлекләрдән бер өзекне укыгач, Нурислам бабамның игелекле булуын аңладым. “Колхоз ашату өчен бәрәңге бирә. Баз казып бәрәңгене шунда саклыйлар. Молотилкада ярылган борчак чәчүгә дә, заданиегә дә яраксыз. Колхоз рәисе Сабиров Нурислам абый балаларны тукландыру өчен шул борчакны һәм он бирә. Он туглап, бәрәңге һәм борчактан пешерелгән аш укучыларны ачлыктан саклап калган. Берәү дә дәрес калдырмый”,--дип язылган анда.

Сугыштан соң, колхозларны эреләндерә башлагач, Нурислам бабам Тыңламас, Өтнә, Иске Иябаш, Әзәк авылларыннан берләшкән “Амур” колхозында рәис булып эшли. Каты авырудан соң, 1959 елда үлеп китә. Аның бертуганнары да авылда яшәп хезмәт иткәннәр. Бертуганы Хаҗәр апа 1953-1957 елларда авыл советы рәисе, соңрак сельпо рәисе булып эшләгән.

Нурислам бабайның 10 баласы туган: Гөлсәхрә, Рәсимә, Нурзада, Вәдүт, Үзбәк, Рузия, Нурзия, Гөлзада, Әлфия, Фәрит. Заманалар үзгәргән, бабайның күпчелек балалары шәһәргә киткән.

Төп нигездә Фәрит бабам кала. Тугызынчы булып дөньяга килгән Фәрит бабай яшь вакытында шофер, соңрак ферма мөдире булып эшли. Авылның иң чибәр һәм уңган кызына өйләнә ул.

Әбием Сабирова Зөһрә Зиннур кызы 1950 нче елның 19 январенда Казиле авылында туа. 1957 нче елда укырга керә. 1961-1967 нче елларда Күпербаш сигезьеллык мәктәбендә укый. Мәктәпне бетерүгә авылда сыер сава башлый. Урта мәктәпне кичке мәктәптә укып тәмамлый. Бик яшь булуына кармастан, әбием зур хезмәт уңышларына ирешә. Һәр сыердан 3068 кг сөт савып “1968 нче елда районның иң яхшы сыер савучысы” почетлы исеменә лаек була. 1971 нче елда ике медаль белән бүләкләнә: “За трудовое отличие” һәм В.И.Ленинның 100 еллыгы уңаеннан чыгарылган юбилей медале. Лаеклы ялга чыкканчы фермада эшли ул.

Фәрит бабай белән Зөһрә әби 3 бала тәрбияләп үстерәләр: Зилә, Альберт, Айдар. Зилә апа да, Альберт абый да гаиләләре белән Казиледә яшиләр. Әнием Гөлназга өйләнгәч, әтием Түбән Мәтәскә авылына өй сала. Безнең гаилә шунда яши башлый.

*Эти-әнием – горурлыгым минем.*

Әтием Айдар мин укыган Түбән Мәтәскә урта мәктәбендә белем алган. Мәктәпне тәмамлагач, Казанда авыл хуҗалыгы институтында белем ала. Яшьрәк вакытта үзен төрле эшләрдә сынап карый. 2003 елда өйләнә. Әнием Гөлназ белән өч балага гомер бирәлә: Азалия, Айгизә, Аяз.

2010 елда алар әнием Гөлназ белән гаилә фермасы эшен башлап җибәрәләр. Беренче елны терлек азыгын үстерәләр. 2011 елдан гаилә фермалары программасында катнашып, грант оталар. Анда алар арчалылар арасында беренчеләрдән булып катнаша. Шуннан соң ферма төзи башлыйлар.

Бүген гаилә фермасының чәчүлек мәйданы 800 гектардан артык. 100 баш сыер асрыйлар. Сауган сөтне халык бик теләп ала. Сөт продукцияләрен Казандагы Агросәнәгать паркында да, узган ел гына ачылган Арчадагы “Лавка фермера” кибетендә дә саталар.

Гаилә фермасында кадрлар белән дә кытлык юк. Кышын дүрт эшче хезмәт куйса, җәй көне аларның саны биш тапкырга арта. Ферма территориясендәге юлларны төзергә дә республика булышты. Ә Арча районы администрациясе исә ферма төзелешендә бик нык ярдәм итте. Әтием Айдар бүгенге көндә Казиле һәм Түбән Мәтәскә авылларын берләштергән “Казанка” агрофирмасын оештырып йөри.

Әнием Гөлназ укытучылар гаиләсеннән. Әбием Якупова Хәнифә Зиннәт кызы Наласа авылында туган. Элегрәк башлангыч классларда, соңрак өлкән классларда тарих укытучысы булып эшли. Бабаем Якупов Ренат Габделбәр улы Балтач районы Арбор авылыннан. Озак еллар математика укытучысы булып эшләгән.

Әнием хатын-кыз фермер буларак «2013 елда иң яхшы гаилә сөт фермасы” номинациясендә республика конкурсы йомгаклары буенча “Ел Хатын-кызы, Ел Ир-аты: Хатын-кыз – бизнес – леди” номинациясендә Хатын-кыз карашы» республика конкурсында җиңүче булып танылды.

## Йомгаклау

Эшемне йомгаклап шуны әйтәсем килә: мин бүгенге көндә, аллага шөкер, тулы гаиләдә яшим. Мине авырганда башымнан сыйпарга йомшак куллы әнием, киңәшләр бирергә акыллы әтием бар. Ирешкән уңышларым, шатлыкларымны уртаклашырга, миңа ярдәм итәргә гаиләм бар. Мин шулар белән үземне бәхетле саныйм.

Нәселебезнең шәҗәрәсен төзү дәверендә мин эти-әнием, әби-бабайларым, туганнарым белән аралашып үзем өчен күп ачышлар ясадым. Күпме туганнарым барлыгын белдем, аларның һөнәрләре, ил алдындагы намуслы хезмәтләре турында күпме матур сүз ишеттем. Һәм шундый нәтиҗәгә килдем: бабаларымның, туганнарымның гаиләләре нык, бердәм булган. Алар тормыш авырлыкларына бирешмичә үзләренә дөрес, туры юл тапканнар, белемгә омтылганнар, игелекле эшләр башкарганнар.

Энем Аяз Сабировлар нәселенең алтынчы буыны дәвамчысы. Сабирҗан бабайның этисе Мостафа бабай турында әлегә бернәрсә дә белмәдек, аннан элегрәк буыннар турында да белүче табылмады. Үскәч, бәлки, архивлардан эзләп булыр. Шәҗәрә төзү миңа бик охшады. Шәҗәрәбезне өйбезнең түренә урнаштырдык. Мәктәптә үткән шәҗәрәләр кичәсендә зур класс укучылары этиләре һәм әниләре ягыннан төзелгән зур шәҗәрәләре турында сөйләделәр. Мин дә киләчәктә әнием Гөлназ ягыннан да нәсел агачын төзергә булдым.

Эзләнү эшемне интернеттан тапкан (кызганыч, авторы күрсәтелмәгән) шигырь юллары белән тәмамлыйсым килә:

Җиде буын бабаңны да
Белү бик кирәк диләр.
Аларның яшәү дәверен
Истә тотарга кирәк.
Әби – бабай исән чакта

Белеп калырга тырыш.
Бездән соңгы буынга да
Тапшыру – олы бурыч.

*Кулланылган әдәбият исемлеге*

1. http://agro.tatarstan.ru/tat/index.htm/news/390111.htm
2. http://intertat.ru/tt/society-tt/item/42934.html
3. Арча районы Түбән Мәтәскә урта мәктәбе музее сайты. http://nmsosh.wixsite.com/meteskimuzei/m-ndesh (соңгы керү 21.03.2018
4. Арча районы Түбән Мәтәскә урта мәктәбе музее материаллары.
5. Казиле авылында яшәүче Сабиров Фәрит бабам һәм Сабирова Зөһрә әбием истәлекләре.

## АЛАР – КЫҢГЫРАУЛЫ МӘКТӘП ИЛЕННӘН

*Сабирова Айзилә Рәшидовна,11 сыйныф*
*Фәнни җитәкче - Сабирова Айгөл Фәритовна,*
*Арча районы МГББУ " Яңа Кенәр урта мәктәбе"*

**Кереш. Укытучы хезмәте- мактауга лаек хезмәтләрнең берсе**

"Үткәнен белмәгән халыкның киләчәге юк", - диләр. Чыннан да ни өчен кирәк икән ул үткәнне белү,тарихны өйрәнү,нәсел-ыру җепләре белән кызыксыну? Күренекле тарихчы Шиһабетдин Мәрҗанинең "Үткәнгә күзе җиткән, киләчәккә үзе җитә",- дигән бик гыйбрәтле сүзләре бар.Димәк,киләчәгеңне төзү өчен үткәнеңне белергә кирәк. Кем булган синең бабаларың? Алар тарихта нинди эз калдырганнар? Аларның хезмәтен дәвам итүчеләр бармы нәселдә? Мин еш кына үземнең әни ни өчен укытучы булган икән дип уйланам. Бәләкәй чакта мин укытучы булуы бик җиңелдер дип уйлый идем. Ләкин үсә төшкәч шуны аңладым: һәркемдә дә укытучы булырга сәләт булмый икән. Бик түземле, башкалар белән аралаша белүче һәм белемле кешеләр генә укытучы була ала. Укытучы хезмәте- миңа бик таныш. Чөнки, әнием, Сабирова Айгөл Фәрит кызы, 18 ел Яңа Кенәр урта мәктәбендә инглиз теле укытучысы булып эшли Ул ачык йөзле, итагатьле, сабыр, һәр балага ярдәм кулы сузарга әзер тора. Мин мәктәп тормышын,дәрескә әзерләнүләрне мәктәптә генә түгел,ә өйдә дә күреп торам. Шуңа күрә укытучы һөнәре бик авыр һәм җаваплы, ләкин иң дәрәҗәле һөнәрләрнең берседер дип саныйм.Чөнки җир йөзендәге барлык һөнәр кешеләренә дә бер олугъ зат – Укытучы белем һәм тәрбия биргән. Мөгаллимнәр ак кәгазь бите кебек сабый күңеленә беренче орлыкны сибәләр. Аларның шытып чыгуы өчен шартлар тудыралар, үскәнен күзәтәләр. Соңыннан мул уңыш җыеп алуына куанучы кешеләр дә бит алар. Укытучы җәмгыятьнең киләчәген әзерли.Укытучы илебезнең киләчәген кайгырта,ил һәм милләт гаме белән яши,шәхси тормышын мәктәп тормышыннан аерылгысыз итеп күрә.Укытучы хезмәте- сайлаган һөнәр генә түгел,бу-укытучы шәхесенең сайлаган язмышы да һәм ул үзенең **актуальлелеген** югалтмый. Җыеп кына әйткәндә, иң зур хөрмәт һәм мактауга лаек кешеләр алар. Менә шуларны уйлап мин үзебезнең нәселдәге укытучылар династиясе турында эзләнү-тикшеренү эшен башлап җибәрдем. Аның **максаты** - төрле чыганаклар аша нәселемдәге укытучыларны барлау; аларның эшчәнлеген өйрәнү , укытучылар династиясенең чылбырын төзү. **Бурычлары** – нәселебез тарихына кагылышлы мәгълүматлар, фоторәсемнәрне туплау, электрон форматка күчерү, саклау һәм киләчәк буыннарга тапшыру, туган як тарихын өйрәнүдә файдалану. Әлеге хезмәтне эшләгәндә миңа дәү этием Фәрит Вафинның туплаган истәлекләре, хәтирәләре, җыйган мәгълүматлары терәк булды.

**Төп өлеш. Дәү этиемнең- 40 еллык фидакарь һәм тугры хезмәте**



Әниемнең әтисе белән әнисе-икесе дә укытучылар. Алар: Вафин Фәрит Вәдүт улы-минем дәү әти, Вафина Марзия Галимҗановна-минем дәү әни. Димәк,минем әни-Сабирова Айгөл Фәрит кызы чын укытучылар гаиләсендә туып-үскән кеше.Дәү әти белән дәү әни икесе дә 70нче еллар башында Казан дәүләт университетында укып белем алган югары белемле филологлар,татар теле һәм әдәбияты укытучылары.Дәү әни инде эшләми,лаеклы ялда,ә дәү әти пенсиядә булса да әле эшләвен дәвам итеп, Яңа Кенәр интернат-мәктәбендәге балаларга татар теле һәм әдәбиятын укыта.

Гаиләбездәге иң күренекле кеше, оста педагог буларак, аның тормыш юлы һәм эшчәнлегенә аерым тукталасым килә. Минем дәү эти-Вафин Фәрит Вәдүт улы – 1954нче елның 2 августында Арча районының Носы авылында туган.Шушы авылда беренче сыйныфка укырга кергән. Әти-әниләре Носы сигезьеллык мәктәбендә укытучы булып эшләгәннәр. Әтисе-Вафин Вәдүт Җәләй улы- татар теле һәм әдәбияты,ә әнисе- Вафина Мәдинә Габдрафыйкъ кызы башлангыч сыйныф балаларын укытканнар.Носыда сигез ел укыганнан соң Фәрит Вафин укуын Шушмабаш урта мәктәбендә дәвам итеп,урта белем ала һәм 1972 елны Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга керә.5 ел шунда укый.Укыганда экспедицияләрдә йөреп,халык авыз иҗатын җыю белән шөгыльләнә,үзешчән сәнгатьтә актив катнаша.Ул чорда университетта “Әдәби сүз” дигән газета чыккан.Ул шунда үзенең беренче хикәяләрен бастыра башлый.Ләкин аңарчы да инде,10 сыйныфта укыганда ук,  Вафин Фәритнең язмалары районның “Коммунизмга” ( хәзерге “Арча хәбәрләре” ) газетасында күренә башлый. Аның беренче “Матурлык” дигән хикәясе дә 1972 елны шушы газетада басылып чыга.

Фәрит Вафинның авыл язмышы;тел-милләт турындагы уйланулары;мәктәп һәм укыту-тәрбия мәсьәләләренә кагылышлы язмалары республиканың “Татарстан яшьләре”, “Безнең гәҗит”, “Шәһри Казан” газеталарында басылган.Бүгенге көндә ул “Татарстан яшьләре” белән хезмәттәшлек итә һәм аның ул газетада 200гә якын язмасы басылып чыккан. Кырык елдан артык мәктәптә эшләгән Фәрит Вафинның укыту-тәрбия турындагы фикерләре дә бик кызыклы.”Мәгариф” журналында ул үзенең татар теле һәм әдәбиятын укыту тәҗрибәсе белән уртаклаша.2008 елда “Мәгариф” журналы уздырган бәйгедә Фәрит Вафин “Иң яхшы мәкалә авторы” җиңүчесе була һәм Диплом белән бүләкләнә.Бу журналда аның барлыгы  18 мәкаләсе басылып чыга.



Фәрит Вафин -кыска юмористик хикәяләр остасы да. Бүгенге көндә аның республика газеталарында басылып чыккан кырыкка якын юмористик хикәясе бар Күбесе мәктәптәге җитешсезлекләр һәм тормыштагы тискәре күренешләрдән көлүгә корылган.  Ул - нәфис сүз остасы да.Матур итеп шигырьләр укый,кеше сокланып карарлык итеп концертлар да алып бара.Элегрәк елларда авыл сәхнәсендә дәү әни белән бергәләп спектакльләр куеп йөргәннәр.Ә яшь чакларында үзешчән сәнгать белән Мәскәүнең үзенә кадәр барып җиткәннәр алар.Халык Хуҗалыгы Казанышлары Күргәзмәсе сәхнәсендә чыгыш ясап,лауреатлар булганнар. Дәү эти белән дәү әнинең сәхнә сөюләре  миңа да йоккан күрәсең.Мин үзем дә сәхнәдә чыгыш ясарга бик яратам,спектакльләрдә уйныйм һәм концертларда җырлыйм.

**Вафиннар – укытучылар нәселе**

Бу шөгыль безгә дәү әтинең әтисе Вәдүт Җәләй улыннан күчкән булырга тиеш.Ул 1952нче елда Укытучылар институтын тәмамлаганнан соң Арча районының Носы сигезьеллык мәктәбендә татар теле һәм әдәбияты укыта башлый.Шушында ул Шекә кызы,башлангыч сыйныфларда укытучы, Мәдинә белән очраша.1953 елда алар өйләнешәләр һәм 1954 елның 2 августында аларның беренче балалары-минем дәү эти-Фәрит дөньяга

килә.Дәү әтинең сөйләве буенча,ул заманнарда укытучылар мәктәптә укытып кына калмаганнар, ә бик күп җәмәгать эшләре дә алып барганнар.Унйортлыкларда агитатор булып эшләгәннәр,бәйрәм саен авыл клубында лекцияләр укыганнар,концертлар куйганнар.Дәү әтинең әтисе спектакльләр куярга бик һәвәс булган,ел саен Носы һәм тирә-як авылларны спектакльләр куеп сөендергәннәр.Носы сигезьеллык мәктәбен тәмамлаган фән докторлары Җәүдәт Фәйзрахманов һәм Рафис Корбанов бөтен фән дөньясына билгеле шәхесләр.Алар Вәдүт Җәләй улында укыганнар,аның дәресләрендә әдәби әсәрләрнең матурлыгын күргәннәр,шигырь-хикәяләрнең аһәңен ишетергә өйрәнгәннәр.

Бакчачы гөлбакчада үскән гүзәл гөлләре белән мактанса,укытучылар да чәчәкләре җимешләнгән укучылары белән горурлана.Шулай булмый ни,бер бала тәрбияләп үстерү генә дә ни тора,ә дистәләгән-йөзләгән нарасыйны җәмгыятькә кеше итеп әзерләп бирү күпме көч,күпме сабырлык,никадәр нур сорый?! Шул фидакарьлек,күңел юмартлыгы элек-электән аерып торган бит инде чын мөгаллимнәрне!

Вафин Вәдүт Җәләй улының ике абыйсы да –укытучылар булган.Олы абыйсы-Вафин Шамил Җәләй улы-химия-биология укытучысы.Гомере буе Яңа Кырлай авылында яшәп,шунда тормышын балалар укытуга багышлаган кеше.Икенче абыйсы Вафин Ясәви Җәләй улы Яңа Кенәр авылында яшәп,татар теле һәм әдәбиятын укыткан.Тормыш иптәше Сания апа белән ике кыз тәрбияләп үстергәннәр. Олы кызлары Сафиуллина Фәймә күп еллар Яңа Кенәр урта мәктәбендә рус теле һәм әдәбияты укытты.Аның кызы Энҗе ,шулай ук, рус теле һәм әдәбияты укытучысы.

Вафиннарның бу буыны Сталин репрессияләренең бөтен авырлыгын,җәбер-золымын үз җилкәсендә күтәргән гаилә.Аларның әтиләре Җәләй бабай сәүдә эше белән шөгыльләнгәне өчен 1930 елда өеннән 6 баласы белән куып чыгарылып,Себергә сөргенгә сөрелә.Үзе шунда ачлыктан үлеп кала,ә балалар могҗиза белән генә исән калып, 1933 елда туган җиргә кайтып төшәләр. Ачлык та,ялангачлык та,кешеләрнең кимсетүләре дә сындырмаган аларны.Теш-тырнаклары белән тормышка ябышып,белем алганнар,халык арасында абруй казанганнар,меңәрләгән сабыйга белем-тәрбия биреп, бөтен гомерләрен аң-белем таратуга багышлаганнар.Дәү әтинең шундый туганнары булганга ничек горурланмыйсың да,ничек сокланмыйсың,ди.Өстәвенә өчесенең дә балалары әти-әниләренең хезмәт юлын дәвам иткәннәр.Татар теле,рус теле,биология укытучылар булып эшләп,бүгенге көндә пенсиядә оныкларын тәрбияләп,матур гына яшәп яталар.Дәү әти ягыннан ике туган апабыз,химия фәннәре докторы Ләйлә Габдрахманова,бүгенге көндә студентларга белем бирә.Ул- нәселебезнең горурлыгы!

Дәү әтинең әнисе ягыннан булган кыз туганнары шулай ук укытучылар.Иң өлкәне - Мөнәвәрә апа Каратай авылында яшәп,пенсиягә чыкканчы шундагы башлангыч мәктәпнең мөдире һәм укытучы булып эшли.Аның ире Васыйл озак еллар Апаз урта мәктәбе директоры булып эшләгән.Өч улларын мәгълүм шәхесләр итеп үстерә алганнар.Өлкән уллары, танылган травматолог, Рөстәм Зәйнуллин инде вафат.Уртанчысы-Илнур Зәйнуллин РКБ хирургия бүлегеν җитәкли. Кечесе Таһир- авыл җирлеге башлыгы.

Кыз туганнарның кечесе Рания апа бүгенге көндә Арчада яши.Шулай ук гомере буе мәктәптә химия-биология укытып,лаеклы ялга чыккан укытучы.Аның кызы Алия , әнисе юлын дәвам итеп, инглиз теле укытучысы булып эшли.Шулай итеп,дәү әти ягыннан мин 19 укытучы барлыгын ачыкладым.Аларның һәрберсе турында аерым китап язарлык.Чөнки 30-35 еллык хезмәт чорында алар меңәрләгән балага белем-тәрбия биреп,кулларыннан тотып язарга өйрәтеп,һәрберсен олы тормышка аяк бастырганнар.Кемнәр генә юк икән алар укыткан укучылар арасында?!

**Укытучылар династиясе дәвам итә**

Дәү әнием Марзия Галимҗан кызының нәсел чылбыры да укытучыларга бай. Аның бабасы Шакир улы Хисаметдин атаклы Кышкар мәдрәсәсендә укыган. Бик белемле, укымышлы кеше булган. Революциягә кадәрле елларда Яңа Ашыт авылында мулла вазифаларын да башкарган.Хатыны Гарифәбану белән балаларына ныклы белем бирергә тырышканнар. Олы кызлары, дәү әнинең әнисе, Хисамова Рабига Ишнарат авылындагы

башлангыч мәктәптә укыткан.Әдәбият дөньясында мәгълүм тәнкыйтьче-язучы Фәрваз Миңнуллинның беренче укытучысы булган ул.Рабиганың абыйсы Хисамов Гыйльметдин Хисаметдин улы-тарих укытучысы , Бөек Ватан сугышында батырларча һәлак була. Рәбиганың сеңлесе Зәйтүнә кызы Мөнирә Лотфиевна Арчаның икенче номерлы мәктәбендә физика-математика укытучысы булып эшли. Ә Рәбиганың энесе Зиннурның улы Алмаз Шакиров- география укытучысы, аның тормыш иптәше- Гөлфирә технология фәнен укыта. Икетуган сеңлесе Бибимәсүфаның кызы Зәйнәпбану- татар теле укытучысы.

Дәү әнием Марзия Яңа Кенәр урта мәктәбен тәмамлагач, Ташкичү мәктәбендә география фәнен укыта. Әмма югары белем алуга омтылыш аны 1969нчы елда Казан дәүләт университетына алып килә.Монда ул татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга керә һәм биш ел дәверендә белем ала. Диплом алганнан соң, үз якларындагы Шушмабаш урта мәктәбенә укытырга кайта . Шушында язмыш аларны дәү әтием белән очраштыра һәм озак та үтми укытучылар династиясен дәвам итүче тагын бер гаилә барлыкка килә. Шулай итеп, әнинең әнисе ягыннан 7 укытучыны ачыкладым мин.

**Йомгаклау**

Нәтиҗәдә ,безнең нәселдә өч буынга 26 укытучы барлыгын белдем.Үзе бер сыйныф дигән сүз. Һәрберсе уртача 30-35 ел хезмәт куйган булсалар гына да якынча 875 еллык педагогик стаж килеп чыга!

Гаиләбездәге укытучыларны, башка мәгълүматларны өйрәнгәннән соң, түбәндәге нәтиҗәгә килдем:

1. Нәселебездәге укытучыларны барлаганнан соң минем йөрәгемдә алар белән горурлану хисләре барлыкка килде.
2. Хәзерге заманда укытучы һөнәре бик авыр булуга карамастан,укытучылар династиясе дәвам итә.
3. Нәселебез турында үзем белгәннәрне сакларга, үземнән соң киләчәк буыннарга тапшырып калдырырга тиешмен мин.



Укытучы туганнарым... Бүген галим дә, ташчы да, иген игүче дә сезнең олы исемегез алдында баш ия, чөнки теләсә кайсы һөнәргә юл башы сезнең фидакарь хезмәтегез нәтиҗәсендә салынган. Сез дөньядагы барлык уңай сыйфатларны үзегезгә туплагансыз. Киң күңеллелек, тырышлык, кешеләргә чиксез мәхәббәт... Укытучыдагы сабырлык аналар сабырлыгына тиң. Нинди авыр елларда да бөтен көчләрен,сәламәтлекләрен балалар тәрбияләүгә биргәннәр,киләчәк буыннар белемле,гыйлемле булсыннар дип тырышканнар.Үз балаларында,оныкларында укытучы һөнәренә мәхәббәт тудырганнар,нәсел җебен өзмичә дәвам итүчеләрне үстергәннәр. Рәхмәт Сезгә, хөрмәтле, кадерле укытучыларым...туганнарым!..Мин дә сездән үрнәк алып укытучы һөнәрен сайлармын, укытучылар династиясен дәвам итәрмен.

*Кулланылган әдәбият исемлеге*

1. Арча төбәге тарихы. – Казан . Татарстан китап нәшрияты, 1996.
2. Вафин Фәритнең гаилә архивындагы истәлекләр.
3. Вафина Марзиянең гаилә архивындагы истәлекләр.
4. “ Мин- кыңгыраулы мәктәп иленнән” . Татарстан яшьләре газетасы, 31 июль, 2014.
5. “ Мөгаллим язмалары” сайты . **faritvafin.ucoz.ru.**

# ПРОГРАММА ВНЕУРОЧНОЙ ДЕЯТЕЛЬНОСТИ “РУКОДЕЛИЕ”

*Сабирова Залия Рафаиловна*
*МБОУ КСШ №3 г. Кукмор РТ*

В проекте Федерального компонента государственного Образовательного стандарта общего образования одной из целей, связанных с модернизацией содержания общего образования, является гуманистическая направленность образования. Она обуславливает личностно-ориентированную модель взаимодействия, развитие личности ребёнка, его творческого потенциала. Процесс глубоких перемен, происходящих в современном образовании, выдвигает в качестве приоритетной проблему развития творчества, мышления, способствующего формированию разносторонне-развитой личности, отличающейся неповторимостью, оригинальностью.

Что же понимается под творческими способностями?

В педагогической энциклопедии творческие способности определяются как способности к созданию оригинального продукта, изделия, в процессе работы над которыми самостоятельно применены усвоенные знания, умения, навыки, проявляются хотя бы в минимальном отступлении от образца индивидуальность, художество.

Одной из главных задач обучения и воспитания детей на занятиях является обогащение мировосприятия воспитанника, т.е. развитие творческой культуры ребенка (развитие творческого нестандартного подхода к реализации задания, воспитание трудолюбия, интереса к практической деятельности, радости созидания и открытия для себя что-то нового Рукоделие, развивающее художественный вкус и умение, воспитывающее терпение, приучающее к аккуратности, обогащает нашу внутреннюю жизнь и приносит истинное удовольствие от выполненной работы. Изделия ручного труда в нашей стране обретают свою ценность и превосходство над серийными промышленными образцами.

Работа в кружке «Рукоделие» - прекрасное средство развития творчества, умственных способностей, эстетического вкуса, а также конструкторского мышления детей.

Одним из видов рукоделия является вязание. Умение вязать всегда пригодится в жизни. Посещение кружка «Рукоделие» научит вязать самые разнообразные и нужные вещи.

После войны дедушка Нурмухамед тоже трудился в колхозе, был бригадиром, отличным работником. Женился на Фазиле, у них родилась дочь – моя бабушка Кадрия. А вот сына увидеть ему не удалось, оставив беременную жену с двухлетней дочерью на руках, он ушел из жизни… не вернулся с поля в февральскую метель 1952 года. В ту ночь они со своим односельчанином потеряли дорогу, дедушка сошел с обоза, чтобы найти тропинку домой…не нашел, а его спутника лошадь привела в деревню. Горечь утраты всю жизнь живет в сердце бабушки, поэтому каждая вещь, касающаяся дедушки дорога нам…[12]

Дорого и фронтовое письмо, полученное от брата дедушки Нурмухамета.

Салахов Зиятдин Салахович родился в 1916 году [15]. В семье был старшим из сыновей. Рассказывают, он был трудолюбивым, старательным [13]. В свое время, как все мужчины, отслужил в армии, и поэтому он оказался в рядах первых защитников Отечества. Сохранилось его письмо, написанное 6 августа 1941 года в вагоне поезда, направлявшегося из Казани на фронт. Через десятилетия слышится я голос солдата: «Из нашей деревни нас девять человек. Держимся вместе. Незвестно куда именно мы едем … ». Пожелтевшие страницы передают надежду, любовь, благодарность: «Вернуться бы живыми …. Очень дороги родные края… Хорошо, что никому плохого мы, братья, никогда не делали. Спасибо, мама, что вырастила нас такими.» Едущий в неизвестность находит силы успокаивать свою мать: «Не беспокойся за нас, мама, будем живы – вернемся». Не суждено было Зиятдину Салахову увидеть родных и близких, не суждено



было ему прийти с поля боя и поклониться отчему дому… «Пропал без вести…- это все, что знала о нем семья [13]. Только недавно руководитель школьного музея Халим Хасанович выяснил, что погиб брат моего деда в 1943 году. [14]

**III. Заключение.**

Таким образом, исследование показало, как тесно связана история нашей семьи с историей страны. Наши прадеды, их братья делали все от них зависящее для приближения Победы в Великой Отечественной войне, для нашего счастливого будущего.

Наш прадед Садриев Гали Садриевич, 1925 года рождения, был призван Мамадышским РВК в январе 1943 года. Рядовой стрелок охранял границы страны на берегах Амура. С 9 августа 1945 года по 3 сентября 1945 года участвовал в войне с Японией. Демобилизован 15 февраля 1948 года. Умер в 2016 году.

Прадед Салахов Нурмухамет Салахович, 1925 года рождения, был призван на фронт в январе 1943 года. Служил артеллеристом. Участвовал в освобождении Польши. День Победы встретил в Варшаве. Умер в 1952 году.

Брат прадеда Салахов Зиятдин Салахович, 1916 года рождения, ушел на фронт в августе 1941 года. Не вернулся с войны. Семья считала его без вести пропавшим. Руководитель школьного музея Халим Хасанович выяснил, что погиб брат моего деда в 1943 году.

Все, кто остался на поле боя, и все, кто, пройдя через ад войны, вернулся домой, считали, что они просто выполнили долг перед Родиной. Выполнили долг… А сколько героизма, терпения, мужества нужно для этого.

Мы будем вечно помнить…

*Список спользованной литературы*

1. Солдатская книжка Садриева Гали Садриевича. Выдан 8 февраля 1948 года.
2. Учетно-послужная карточка Садриева Гали Садриевича. 1963 г.
3. Военный билет Садриева Гали Садриевича. Выдан 31 октября 1963 года.
4. Удостоверение о награждении медалью «За победу над Японией». 1945 год.
5. Свидетельство о заключении брака. Выдан 10 февраля 1975 года.
6. Удостоверение о награждении медалью «Ветеран Труда». 1988 год.
7. Свидетельство о смерти. Выдан в ноябре 2014 года.
8. Архив семьи Садриева Гали Садриевича.
9. Воспоминания Садриева Гали Садриевича, 1925 года рождения, записанные до его смерти
10. Свидетельство о заключении брака. Выдано 8 сентября 1950 года
11. Архив семьи Салахова Нурмухамета Салаховича
12. Воспоминания Садриевой (в девичестве Салаховой) Кадрии Нурмухаметовны,1950 года рождения
13. Материалы из архива семьи Салахова Мустафы Салаховича, предоставленные его дочерью Гафуровой Ракией Мустафовной
14. Материалы музея МБОУ «Нижнеошминская СОШ» Мамадышского района РТ ( руководитель Салахутдинов Халим Хасанович)
15. Книга памяти. Издательство «Книга памяти», 1995 г. Стр.197.

## МИНЕМ ГАИЛӘМ – МИНЕМ ГОРУРЛЫГЫМ

*Сафаргалиева Тансылу Рафис кызы, 10 класс*
*Фәнни җитәкче - Мухарлямова Чулпан Хатиповна, Саба муниципаль районы*
*“И.С.Башкиров исемендәге Завод-Нырты урта гомумбелем бирү мәктәбе»*

Укытучы хезмәте...Күпме кичерешләр, шатлык, өмет салынган аңа. Бик тынгысыз, зур җаваплылык сорый торган эш.

Укытучы ул бүгенге буын белән киләчәк арасында күпер салучы, җәмгыятебез алдында аңа зур җаваплылык йөкләнгән.Чөнки кеше аларга үзенең иң кадерлесен-газизенең язмышын ышанып тапшыра. Шуңа күрә алардан һәрвакыт балалар белән бергә булу, кешелек тарихы туплаган белем хәзинәсе аша аларда дөньяга аңлы караш, хезмәткә хөрмәт, югары әхлак сыйфатлары тәрбияләү сорала.

Авылымда туып-үскән, анда яши, эшли торган кемне генә очратма, аларның һәрберсе үзенең туган ягын, аның кешеләрен, әлбәттә, иң беренче чиратта, укытучыларын, мәктәбен зур горурлык хисе белән искә ала. Горурланмаслык та түгел шул. Анда үз эшенә бирелгән, тырыш, уңган мөгаллимнәр эшли. Шундыйларның рәтенә иң беренче чиратта мин үз гаиләмнең укытучыларын кертер идем.

**Эшнең максаты**- укытучылар тормышын төрле яклап ачарга.

**Бурычлар:**

1. Укытучы гаиләсе белән әңгәмә оештыру.
2. Әлеге мөгаллимнәр гаиләсе турындагы мәгълүматны анализларга һәм тарихи справка төзергә.

**Эшнең структурасы**: план, кереш, төп өлеш, йомгак, кулланылган әдәбият, документлар һәм фотосүрәтләрдән тора.

**Эшнең актуаллеге:** 2010 нчы ел Татарстан республикасында - укытучы елы булып тарихка кереп калды, шуңа күрә бу эшне укытучылар династиясенә багышлау бик дөрес дип саныйм. Мөгәллимнәр династиясе белән аларның гаилә әгъзаләре генә түгел, шулай ук башка кешеләрдә хәбәрдар булырга тиештер дип уйлыйм.

**1.“Мөгәллимнәр династиясенә” аңлатма**

Гаилә тарихы күп еллар буе киң таралган жанр булып санала. Үз эченә ул кешеләр өчен мөһим булган вакыйгаларны: балалар тууын, гаиләнең барлыкка килүен, профессиональ өлкәдәге казанышларны һәм башка төрлә өстәмә мәгълүматлар кертә. Династия турында тупланган мәгълүматлар аларның гаилә әгъзалары өчен генә түгел, шулай ук киләсе буын өчен дә кызыклы.

Гаилә тарихын өйрәнгәндә төп урынны гаилә әгъзаларының нинди һөнәр белән шөгелләнүе алып тора. Үзенең әти-әнисенең һөнәрен сайлаган киләсе буынга горурланып, ихтирам хисе белән карыйлар. Үзенең тормышын балаларга белем бирүгә багышлаган кеше ихтирам хисе уята, шуның өчен укытучыларның җәмгыяттә уз урыны бар. Мөгәллимнәр династиясе: гаилә традицияләрен, истәлекле әйберләр турындагы хикәятләрне, газета материаллары һәм башкалар үз эченә ала.

Укытучылар династиясе – гаилә әгъзалары турындагы мәгълүматлар, аларның туганлык дәрәҗәсен ачыклау, гаилә эшен дәвам итүчеләрнең эшчәнлегенә бәяләмә бирү, ягъни династия төзелү турындагы мәгълүматларны туплый.

**2.Сәфәргалиевлар – мөгәллимнәр династиясе**

Безнең нигез Урта Нырты авылында. Әбием Нурания һәм бабам Ханзөфәр Сәфәргалиевлар Нырты төбәгенең фидакарь укытучыларыннан саналдылар. Аларның ике уллары –әтием Рафис һәм Рамил абый, кызлары – Раилә апа да укытучы һөнәрен сайлаганнар. Әнием дә үзләре кебек педагоглар гаиләсеннән. Әниемнең бертуган ике апасы да- укытучылар.

**2.1.Сәфәргалиев Ханзөфәр Сәфәргали улы**

Бабам Ханзөфәр Сәфәргалиев Арча педагогия училищесын тәмамлап, Югары Утар башлангыч мәктәбенә укытырга кайта. Белем дөньясына тәүге адымнарын атлаучы сабыйларга ныклы тәрбия бирү белән бергә, халыкның тормыш-көнкүрешен җиңеләйтергә тырыша, өлкәннәргә шефлык ярдәме оештыра. Шул елларда ул Казан педагогия институтын тәмамлап, югары белем ала.

Озакламый аны Керәнне сигезъеллык мәктәбенә күчерәләр. Берничә айдан үз хезмәтен төгәллек белән башкаручы бабама мәктәп директоры вазифасын кабул итәргә туры килә. Шушы чорда аның коллектив белән эшләү тәҗрибәсе дә туктаусыз камилләшә.

Ә ике елдан дүрт авылны берләштергән Тукай исемендәге колхоз коммунистлары, олы ышаныч күрсәтеп, аны партоешма секретаре итеп сайлыйлар. Соңрак КПСС райкомы бюросы тәкъдиме белән "Саба" совхозына партоешма секретаре итеп тәкъдим ителә. Хәзер инде төп эше әлеге вазифа булган секретарьга хезмәт бермә-бер арта – һәр тармак өчен директор белән бертигез дәрәҗәдә җавап бирә. Шуның өстенә авыл халкын укыту, яшь буынны тәрбияләү көн үзәгендә тора, мәгариф, мәдәният кебек социаль мәсьәләләрдә ярдәм күрсәтү, аларның эшен яхшыртуда даими эзләнү, үз белемеңне күтәрү сорала.

Партия эшчәнлеге тыелганнан соң, ул үзен кабат тулысынча мөгаллимлек эшенә багышлады - әбием Нурания Хәкимҗан кызы белән Урта Нырты башлангыч мәктәбендә кулга-кул тотынышып балаларга белем бирә башлады.

Тынгы белмәүче, һәрвакыт халык арасында эшләүче Ханзөфәр Сәфәргалиевның хезмәте даими мактап телгә алынды һәм югары бәяләнде.Ул хезмәттәге уңышлары өчен күп тапкырлар район, мәгариф бүлеге тарафыннан мактау кәгазьләре белән бүләкләнде.

Бабам тугыз ел элек, каты авырудан соң, вафат булды. Ул гомеренең соңгы сулышына кадәр үзе яшәгән, эшләгән газиз җире, шул төбәкнең халкы өчен җан атып йөрде, авылларның тарихын өйрәнде, кешеләре турында фактлар туплады. 2003 елда аның "Мичәнбашым – туган авылым" дигән һәм 2007 елда, вафатыннан соң, "Нырты ягы – тарихи төбәк" дигән китаплары басылып чыкты.

### 2.2. Сәфәргалиева Нурания Хакимҗан кызы



Әбием Нурания Хәкимҗановна Арча педагогия училищесын тәмамлап, озак еллар Өчиле башлангыч, Керәнне сигезъеллык һәм Урта Нырты башлангыч мәктәпләрендә балалар укытты. Ул барыннан да элек, үз алдына куелган максатларны тормышка ашыру өчен төпле белем бирүче, тирән фикерле, актив җәмәгать эшлеклесе. Балаларга тормышта үз юлын табарга булышучы, тормыш тәҗрибәсе белән башкаларга өлге, бала күңеленә иң якын кеше була алган педагог. 30 елдан артык балаларга белем биргән әбием бүген лаеклы ялда.

### 2.3. Сәфәргалиев Рамил Ханзөфәр улы

Рамил абый –гаиләдә иң өлкән бала. Балалар арасында да иң беренчеләрдән булып ул укытучы һөнәрен сайлый. Рамил Ханзөфәрович башта Арча педагогия училищесын, аннан соң КДПИ ның география бүлеген тәмамлый. Хезмәт юлын ул Завод-Нырты урта мәктәбендә башлый. Берничә ел Урта Нырты башлангыч мәктәбендә дә укыта. Бүгенге көндә 28 ел стажлы педагог , Завод-Нырты урта мәктәбендә география фәненнән белем бирде. Үз хезмәтенең остасы булган Рамил абый башкалар белән тәҗрибә уртаклаша, һөнәри үрнәкләрен тәкъдим итә, киңәшләшә, әнә шулай туктаусыз эзләнүләр аша тәҗрибә туплый, заман белән бергә атлый ул. Хәзерге вакытта ул лаеклы ялда.

### 2.4. Сафаргалиев Рафис Ханзөфәр улы

Әтием Рафис Ханзөфәр улы Сәфәргалиев абыйсы белән апасы укытучы һөнәрен сайлагач, үз юлын бу тармак белән бәйләмәскә була.Һәм Лаеш авыл хуҗалыгы техникумына кереп үзен җир кешесенә багышлый.Совет Армиясендә хәрби бурычын үтәп кайтканнан соң читтән торып Авыл хуҗалыгы академиясен бетерә."Саба" совхозында баш аграном, аннан

Олы Нырты авыл Советы рәисе булып эшли.Әнием белән гаилә корганнан соң аларның уй-теләкләре, кичерешләре мәктәп тормышы белән бәйләнә.Һәм әтиемдә укытучы булу теләге уяна.Ул үзенең теләген чынга ашырып 2 нче югары белем ала, Казан дәүләт педагогия университетының биология факультетына укырга керә.Завод-Нырты, Урта Нырты мәктәпләрендә мәгаллимлек итте.

Әтием киләчәк буын шәхесен үстерүгә, белемле, намуслы кеше әзерләүгә һәрвакыт зур игътибар бирде, яңалыкка даими омтылып эшләде: педагогикада матур казанышларга ирешкән укытучыларның тәҗрибәсен өйрәнүне, үзенең хезмәт алымнарын туктаусыз камилләштерүне изге бурычы итеп куя иде. Хәзерге вакытта әтием Олы Нырты җирле үзидарә башлыгы. Бу эше дә аның мәктәп, балалар бакчасы белән бәйләнгән.Укыту-тәрбия процессында туган проблемаларны чишү юлларын мәктәп директорлары, бакча мөдирләре белән бергә җыелышып уңай хәл итәләр.

**2.5.СәфәргалиеваРаилә Ханзөфәр кызы**

Раилә апа Ханзөфәровна да әти-әнисе һөнәрен үзләштерде. Ул туганнарының гына түгел, үзе укыта торган белем йортының да горурлыгы, таянычы, хөрмәткә лаек кешесе. Хезмәт юлын Урта Нырты башлангыч мәктәбеннән башлады. Бүгенге көндә Казан шәһәренең 2 нче гимназиясендә яшь буынга белем бирә - башлангыч сыйныфларны укыта..

Раилә Ханзөфәровна гади укытучы гына түгел. Кирәк икән кырыс, таләпчән дә була белә, кирәк икән йомшак, шаян, җор күңелле кешегә әйләнә. “Ул безнең әниебез, ә әти-әниләребезнең якын дусты”,- диләр укучылары аның турында.

**2.6. Сәфәргалиева Фирдания Миннемулла кызы**

Әнием Сәфәргалиева (Галялетдинова) Фирдания Миннемулла кызы Завод-Нырты сигезъеллык мәктәбен 1984 елда тәмамлап Арча педагогия училищесына укырга керә. Апалары Фирая һәм Эльмира бу вакытта бу училищены бетереп эшли башлаган булалар инде.Әнием апалары һәм беренче укытучысы Мөнәвәрә Мингаз кызы үрнәгендә укытучы һөнәрен сайлаган. Ул беренче укытучысы турында “Йомшак тавышлы, мөлаем, йөзендә һәрвакыт елмаю булганы өчен без аны бик яраттык”-дип искә төшерә.

Арча педучилищесын 1988 елда тәмамлап хезмәт юлын Завод-Нырты мәктәбендә өлкән пионервожатый булып эшли башлый. Читтән торып КГПИ ның математика һәм информатика факультетын тәмамлый тәмамлый. Әле кайчан гына үзе тәмамлаган мәктәптә укытучы булу бик кыен да, җайлы да була аңа. Бер үк вакытта укытучы да син, укучы да.Үзеңне укыткан укытучылар һәр адымыңны сынап, күзәтеп торалар. Киңәш сорарга туры килсә,алар аңа һәрвакыт ярдәм итәләр. Ул үз эшен бик яратып башкара. Төрле җыеннар,класстан тыш чаралар, истәлекле көннәргә багышлаган кичәләр үткәрә.

Әнием бу гаиләнең төп нигезенә килен булып килүе белән дә бик бәхетле. Әбием Нурания Сәфәргалиева лаеклы ялга чыккач, Урта Нырты башлангыч мәктәбендә чын алмаш булды. Әйткән һәр сүзен тырыш хезмәте белән дәлилли, укучыларга тирән белем һәм тәрбия бирүдә халык педагогикасына мөрәҗәгать итә, укытучы-новаторларның тәҗрибәсен өйрәнә, яңадан-яңа ысуллар эзли, камиллеккә омтыла.

“Өең яхшы булсын дисәң,нигезеннән үк нык сал”, -дигән әйтем бар.Укучыларның белемнәре тирән, ныклы булсын өчен, башлангыч сыйныфларда фәннәрне тирән үзләштерелүе шарт булып тора.Әнием моның өчен бар көчен куя. Безнең, өч кызының беренче укытучысы да – ул минем әнием.Ул сөйкемле, гади, тыйнак. Безне язарга ,укырга өйрәтүче , белем серләренә төшендерүче, акны-карадан , яхшыны-яманнан аерырга өйрәтүче ул.

Һәр баланы үз баласыдай якын күрә.Аларның кайгы-шатлыкларын уртаклаша. Ул 1нче категорияле, ихтирамга лаек укытучы. ”23 ел укыту дәверендә бик күп матур хатирәләргә бай хезмәт юлым бар, укучыларымның тормыштагы уңышына шатланып, күңелле истәлекләргә чумып яшим”, - ди ул горурланып.

**2.7. Галялетдинова Фирая Миннемулла кызы**

Әниемнең апасы Багаутдинова (Галялетдинова) Фирая Миннемулла кызы Арча педагогия училищесын 1980 елда тәмамлый.Читтән торып КГПИ ның рус теле һәм әдәбияты

факультетында белем ала.Кукмара районы Туембаш, Шепшеңәр, Кәчимир авылларында башлангыч мәктәптә укыта.Үзен абруйлы, алдынгы тәҗрибәне кулланып эш итүче, тирән белемле,киң эрудицияле педагог итеп таныта. Ныклы белем бирү белән беррәттән балаларда югары әхлаклылык сыйфатлары, хезмәтне ярату, табигатьне саклау хисләре тәрбияләргә тырыша.

**2.8. Галялетдинова Эльмира Миннемулла кызы**

Ахмадуллина (Галялетдинова) Эльмира Миннемулла кызы 1983 елда Арча педагогия училищесын тәмамлап Завод-Нырты мәктәбендә математика фәненнән укыта башлый. Читтән торып КГПИ ның физика-математика факультетында белем ала. Үз фәненең методикасын бик яхшы белгәнлектән ачык,юллары туры була аның. Һәр балага шәхес итеп карый белә, шуңа да укучылары мөстәкыйль фикерләргә, үз сүзләрен әйтергә, шул ук вакытта яшьтәшләре арасында да бер-берсен тыңлый белергә өйрәнәләр.

**2.9.Гиниятова Нүрзия Хәкимҗан кызы**

Балалар укыту һәм тәрбияләүдә үзеннән зур өлеш керткән һәм 36 ел гомерен балалар күңеленә белем орлыклары чәчүгә багышлаган ветеран укытучы, әбиемнең бертуган апасы Нурзия апа турында язмыйча калу зур хата булыр. Яшь буынга белем бирү эшенә ул бик авыр чорда, 1944 елда, Завод-Нырты җидееллык мәктәбен тәмамлап, Сабада укытучылар үзерләү курсларында укыганнан соң алына. Килдебәк, Оет, Олы Нырты башлангыч мәктәпләрендә балаларны укырга-язарга өйрәтә. “Боз кебек мәктәпкә килеп керә идек, ягырга утын бик аз иде. Парталар юк, акбур юк... Шушындый шартларда балалар ничек тә белемле булырга, без ничек тә белем бирергә тырыша идек...”, - дип бүгенге көн белән чагыштыра ул.

Укыту осталыгын камилләштерүгә, үз белемен күтәрүгә даими игътибар бирә. Башта педагогик училищены, соңыннан читтән торып Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлый. Олы Арташ һәм Завод-Нырты урта мәктәпләрендә татар теле һәм әдәбияты фәненнән укыта. Нурзия апа тел белгече, ягъни филолог буларак бөтен концертларны, төрле чараланы, кичәләрне әзерләү белән дә шогыльләнә..Җырлый да, бии дә, сөйли дә .

Тора-бара Кукмара районының Төркәш авылындагы егеткә кияүгә чыгып шунда күчеп китә. Әмма кайда гына эшләмәсен, ул үз һөнәренең чын остасы итеп танылa. Һәр баланың сәләтен, һәвәс-омтылышын үзенә генә хас сизгерлек белән тоеп, индивидуаль эшли, укучысына шәхес итеп карый белә, мөстәкыйль фикерләргә өйрәтә. Яшь буында туган телгә, халкыбызга тирән мәхәббәт тәрбияләргә тырыша. Лаеклы ялга чыкканчы үз эшен бик яратып башкара. Кызлары Рузалия, Фәнзилә, Рахилә, Диләрә дә мәгариф өлкәсендә кайнап яшиләр, педагогик белемле. Рузалия апа –Кукмара районы хакимият башлыгы урынбасары, Фәнзилә апа- филология фәннәре кандидаты, доцент, Казан дәүләт университетында укыта, Рәхилә Хакимовна- Мамадыш районының Олыяз лицеенда директор урынбасары, Диләрә апа- Кукмара районы мәгариф бүлегендә ИМЦ директоры.

**2.10.Сафаргалиева Минзилә Рафис кызы**

1995 елның 17 декабрендә Урта Нырты авылында дөньяга аваз сала. 2012 елда Завод-Нырты урта мәктәбен тәмамлап, Казан педогогик көллияткә укырга керә. 2016 елда кәллиятне тәмамлап, дәүләт спорт һәм туризм академиясенә читтән торып белем ала. Хәзерге вакытта Казан шәһәренең 69 нчы мәктәбендә физик тәрбия укытучысы булып эшли.

Йомгак

Бер акыл иясе әйткән: Берничә айдан уңыш алыйм дисәң- иген чәч, ун елдан җимеш ашыйм дисәң- агач утырт, җир йөзендә якты эз калдырыйм дисәң- бала укыт. Безнең нәселнең 15 кешесе шушы соңгысын сайлаган.Теләсә кем укытучы була алмый. Мәктәптә эшләү өчен балаларны үз баладай якын күрергә, алар тормышы белән яши белергә, аларның кайгы-шатлыкларын уртаклаша алырга кирәк. Әти-әнием укытучы булгач, безгә дә тырышырга туры килә. Аларның йөзләрен кызартасыбыз, борчыйсыбыз килми. Һәрвакыт әдәпле, тәрбияле, белемле булырга омтылабыз.

2010 ел- Укытучы елы иде. Әмма укытучыга, аның ихтыяҗларына игътибар бу ел белән генә чикләнмәсен иде. Чөнки укытучы җәмгыятнең киләчәген әзерли, ил һәм милләт гаме белән яши, шәхси тормышын мәктәп тормышыннан аерылгысыз итеп күрә. Ул-иң кирәкле, иң гумалы, иң җаваплы һөнәр иясе. Шуңа күрә ул даими игътибарга, хөрмәткә лаек.

*Кулланылган әдәбият*


1. Гатауллин Ш. Барысы да мәктәптән башлана// Яңа аваз № 16 апрель, 1992 ел
2. Сәфәргалиев Х. С. Нырты ягы – тарихи төбәк: Тарихи – публицистик очерк. – Казан: “Дом печати” нәшрияты, 2007. – 76 бит + рәсем.
3. Сәфәргалиев Х.С. Мичәнбашым-туган авылым.Тарихи-публицистик очерк.-Казан:”Матбугат йорты” нәшрияте,-2003.-80 бит.


## ТАТАР ТЕЛЕНДӘ ТӨП ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНДА БЕЛЕМ АЛУЧЫ УКУЧЫЛАР ӨЧЕН “ӘДӘБИ АТНАЛЫК” ТЕМАСЫНА ДӘРЕСТӘН ТЫШ ЭШЧӘНЛЕК ОЕШТЫРУ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ


*Сәләхетдинов Инсаф Исрафил улы,*
*МБГБУ “Шубан төп гомуми белем мәктәбе”,*
*туган тел һәм әдәбияты укытучысы*


Бүгенге көндә белем бирү системасының үзенчәлекле якларыннан берсе- аның укучылар шәхесенә һәм аларның иҗади сәләтләрен үстерүгә юнәлдерелгән булуы. Дәрестә өйрәнелә торган материал дәрес белән генә чикләнми, ул дәрестән тыш эштә дә дәвам ителә. Мәктәптә дәрестән тыш эшләр, гамәлдәге программаларга нигезләнеп, планлы рәвештә алып барыла. Татар әдәбияты үз чиратында – татар халкының чал тарихлы бай рухи хәзинәсе, күңеле матурлыгы, хисләре сафлыгы һәм матур хыялларының үткәне, хәзергесе һәм киләчәгенең сәнгатьчә чагылышы. Шуның өчен дә кайда гына булмасын – гомуми урта белем мәктәпләрендә, шул исәптән рус мәктәпләрендә, гимназияләрдә, махсус урта һәм югары уку йортларында – татар теле һәм әдәбиятын укыту, иң беренче чиратта, телебезнең байлыгына һәм киң мөмкинлекләренә, нәфислегенә, халкыбызның, тел осталарыбызның талантына, сәнгатебезнең камиллегенә соклану хисләре тәрбияләү чарасы булып тора.

***Эшемнең темасы*** – “Татар телендә төп гомуми белем бирү оешмаларында белем алучы укучылар өчен “Әдәби атналык” темасына дәрестән тыш эшчәнлек оештыру үзенчәлекләре”.

***Теманың актуальлеге.*** Сер түгел: соңгы елларда укучыларыбыз күп вакытын компьютер янында иҗтимагый челтәрләрдә үткәрә, көннән-көн азрак укый, күпләре телевизор экранын якын күрә. Шуңа күрә укучыларда әдәбиятка мәхәббәт, кызыксыну тәрбияләүгә игътибарны көчәйтү бүгенге көндә зур әһәмияткә ия һәм актуаль мәсьәләләрнең берсе. Ә бу исә татар теле һәм әдәбияты укытучысының төп бурычларыннан санала. Шунысын да искәртергә кирәк: рус һәм инглиз теленең йогынтысы көчәйгән хәзерге чорда әдәбиятка кызыксыну уяту һәм тәрбияләү укытучыдан шактый катлаулы, эзлекле, дәвамлы эш, игътибар һәм көч таләп итә, тирән белем һәм күнекмәләр булуын, иҗади якын килүне сорый. Тикшеренүгә алынган теманың актуальлеге нәкъ менә шушы факторлар белән билгеләнә.

***Хезмәтнең максаты*** – татар телендә төп гомуми белем бирү оешмаларында белем алучы укучылар өчен “Әдәби атналык” темасына дәрестән тыш эшчәнлек оештыру үзенчәлекләрен өйрәнү.

Максаттан чыгып, түбәндәге ***бурычлар*** куелды:

♦ Дәрестән тыш эшләрне үткәрү принципларына, максат һәм бурычларына күзәтү ясау;

♦ Дәрестән тыш эшчәнлек оештыру эчтәлеге һәм формаларына карата галимнәрнең фикерләрен ачыклау;

♦ Татар телендә төп гомуми белем бирү оешмаларында белем алучы укучылар өчен әдәби атналык эшкәртмәсе һәм төрле методик биремнәр, күнегүләр, уеннар тәкъдим итү.

- Чыгарылыш квалификация эшен язу барышында ***фәнни-методологик нигез*** буларак, Ә.Хуҗиәхмәтов, С.Г.Исмәгыйлева, Ф.С.Вәлиева, Г.Ф.Саттаров, М.В.Фазлуллин, Л.З.Шакирова, Ф.С.Сафиуллина, Ф.Ф.Харисов, Р.А.Юсупов, З.Н. Хәбибуллина, Х.Г. Фәрдиева, В.С.Казыйханов, Р.Ә.Асылгәрәева һәм башка галимнәрнең хезмәтләре кулланылды.

**Проектның максатчан төркеме:**

1-11нче сыйныф укучылары. Укучыларның яше – 7 – 16 яшь.

**Проектны тормышка ашыру вакыты һәм урыны:**

Проект бер атнага исәпләнгән. Проект Балтач районы Шубан төп гомуми белем бирү мәктәбендә мәктәбендә тормышка ашырылачак.

Хезмәтнең ***төзелеше*** кереш, ике бүлектән торган төп өлеш, йомгак, кушымта өлешләреннән гыйбарәт. Кереш өлештә теманың актуальлеге ассызыкланды, эшнең максаты һәм бурычлары билгеләнде, фәнни-методологик нигез күрсәтелде. Беренче бүлектә дәрестән тыш эшләрне үткәрү принциплары, чараларның эчтәлеге һәм формалары турында бәян ителде. Икенче бүлектә татар телендә төп гомуми белем бирү оешмаларында белем алучы укучылар өчен “Әдәби атналык” темасына дәрестән тыш эшчәнлек оештыру үзенчәлекләре өйрәнелде.

## 1. Дәрестән тыш чаралар турында төшенчә

Дәрестән тыш эшчәнлек- мәктәптә белем бирүнең аерылгысыз бер өлеше, ул федераль дәүләт белем стандартын тормышка ашыруда үзенчәлекле роль уйный.

Гомуми белем бирү мәктәбенең чыгарылыш сыйныф укучысы портретын сурәтләп, федераль дәүләт белем стандарты укытучыларга укучылар коллективы белән дәрес һәм дәрестән тыш эшчәнлекне оештыруның төгәл юнәлешләрен күрсәтә.

Федераль дәүләт белем стандарты идеологиясе нигезендә бала шәхесенең үсеше һәр даим укытучылар коллективының игътибар үзәгендә булырга тиеш.

Шуңа күрә дә, федераль дәүләт белем стандартында «дәрестән тыш эшчәнлек» төшенчәсенә, аны оештыру юнәлешләренә махсус урын бирелгән.

Дәрестән тыш эшчәнлек - дәрес кысаларына бикләнмәгән, әмма шул ук вакытта балаларның белемен дә, зиһенен дә үстерә торган, аларның гамәли шөгыльләренә, зәвыкларына, сәләт мөмкинлекләренә уңай тәэсир иткән тәрбияви юнәлешнең бер алымы. Икенче төрле әйткәндә, дәрестән тыш эшчәнлек ул – уку эшчәнлеге кысаларыннан чыккан белем бирү эшчәнлеге, ул класстан тыш та алып барылырга мөмкин, ләкин ул белем бирү кысаларына салынган белемнәрне киңәйтүгә, тирәнәйтүгә, ныгытуга хезмәт итәргә тиеш.

## 2. Дәрестән тыш эшләрне үткәрү принциплары

Дәрестән тыш эшләр гомумдидактик принципларга нигезләнеп оештырыла: максатчанлык, фәннилек, системалылык, эзлеклелек, укучыларның яшь һәм индивидуаль үзенчәлекләре, балаларның мөстәкыйльлелеге һәм иҗади активлыгы, тормыш белән бәйлелек саклана.

Бу белем бирү компонентының эчтәлеге укучыларның сорауларыннан һәм ихтыяҗларыннан чыгып, белем бирү оешмасы тарафыннан үзгәртелеп торырга мөмкин.

Мәктәптә татар теле һәм әдәбияты укытучысының эше җаваплы һәм шактый ук катлаулы.

Тел һәм әдәбият дәресләрен укытуда киеренке эшчәнлек, тирән белем һәм педагогик осталык таләп ителә. Укытучы алдына бик күп бурычлар куела: туган телгә, әдәбиятка мәхәббәт тәрбияләү, аның аша үсеп килүче яшь буында ватанпәрвәр омтылышлар булдыру, башка халыкларның да әдәбиятын белү һәм олылау, сүз сәнгате ярдәмендә безне чолгап алган табигать һәм иҗтимагый тормышта, кешеләр арасындагы үзара мөнәсәбәтләрдә тулып яткан матурлыкны тою кебек олы хисләр тәрбияләү зарурлыгын да искә алсак, укытучы өстенә нинди җаваплы эшләр төшкәнен сиземләве авыр түгел. Бу очракта дәресләр уздыру белән чикләнү һич мөмкин түгел. Системалы һәм планлы рәвештә класстан тыш эшләр дә

оештырырга туры килә. Уку-укыту процессының бу мөһим ягы укучы шәхесен формалаштыруда бик кирәкле, нәтиҗәле чара булып тора. Дәрестән тыш чаралар үткәрү вакытында укучыларга мөстәкыйль, иҗади актив булырга, үзләрен танытырга мөмкинлек туа.

Дәрестән тыш эшләр дәрес алдына куелган белем һәм тәрбия бирү мәсьәләләрен чишүне күз алдында тоталар, һәм аларның төп максаты- укучыларда әдәбиятны тирәннән өйрәнүгә, халыкның рухи хәзинәсеннән мөмкин кадәр тулырак файдаланырга, аны сакларга һәм баетырга омтылыш тудыру.

Дәрестән тыш эшләр уку эшләре кебек үк, гомумдидактик принципларга нигезләнеп оештырылырга тиеш: максатчанлык, фәннилек, системалылык, эзлеклелек, укучыларның яшь һәм индивидуаль үзенчәлекләрен исәпкә алу, балаларның мөстәкыйльлелеге һәм иҗади активлыгы, тормыш белән бәйлелек. Беренчедән, ул ирекле-ихтыяри булырга, ягъни укучыларның үз ихтыярларына тәңгәл килергә тиеш. Әйтик, һәрбер эшне оештыруда, аны үткәрүдә укучы балалар үзләре теләп катнаша, үзләре башлап йөри, үзләре башкаларны әйди икән - бу инде тәрбия эшләренең дә уңышлы барачагына бер ныклы һәм ышанычлы шарт.

Әлбәттә, сыйныфтан тыш эшләрнең дәресләр белән тыгыз бәйләнештә булуын онытмаска кирәк. Чаралар укучыларның әдәбият турындагы белемнәрен киңәйтәләр, тирәнәйтәләр, ныгыталар. Укытучы алдында укучыны җәлеп итү бурычы тора.

**3. Сыйныфтан тыш эшләрнең тематикасы, юнәлешләре, төрләре**

Сыйныфтан тыш эшләрнең тематикасы, юнәлешләре, төрләре бик күп. Мәктәпләрдә түгәрәкләр, әдәби берләшмәләр, татар теле атналыклары, татар халкының бай гореф-гадәтләре, йолалары, халык авыз иҗатына, шагыйрь, язучы, галим, якташ язучылар иҗатына, эшчәнлегенә, туган якны өйрәнүгә, һәм башка бик күп темаларга кичәләр, класстан тыш уку дәресләре, конференцияләр, диспутлар, әдәби очрашулар, бәйгеләр, ярышлар кебек төрле эшләрне оештырырга мөмкинлек бар.

Класстан тыш эшләр системасында иң мөһим, әһәмиятле урынны укучыларның мөстәкыйль укуы белән җитәкчелек итү алып тора. Укытучы укучыларның нәрсә һәм ничек укуларын исәпкә ала, китапханәләр белән һәм китап уку белән бәйле булган класстан тыш эшләр үткәрә, укучыларның яшь һәм индивидуаль үзенчәлекләрен, хәзерлек һәм аңлау дәрәҗәләрен исәпкә алып, укучыга китап сайларга булыша, укылганнар йогынтысында үсү-үзгәрүен күзәтеп тора.

Класстан тыш эш төрләрен мәктәп практикасында гаять зур популярлык казанганнары - **иртәләр һәм кичәләр.** Эшнең бу төрендә укучыларны сан ягыннан да күбрәк катнаштыра алу мөмкинлеге бар. Иреклелек һәм активлылыкның чиге юк. Кызыклы ярышлар, конкурслар, бай эчтәлекле чыгышлар белән укучыларны җәлеп итәргә була. Кичәләр һәм иртәләрне әзерләгәндә, җыр-бию, сәнгатьле сөйләү күнегүләре, спектакльләр күрсәтүгә, инсценировкаларга хәзерлек алып барыла. Кичәләрнең укучыларга тәрбияви йогынтысы да, белем бирү һәм укучыларның сәләтен төрле яктан ачу мөмкинлекләре дә зур.

Кичәләр, иртәләрне төрле темаларга үткәрергә мөмкин. Мәсәлән, эш процессында милли үзаң, милли рух тәрбияләү, туган якны, аның кешеләре белән ныклап танышу, әдипләрнең тормыш юлын, иҗатын өйрәнү, туган тел байлыкларын барлау, аңа карата ярату хисләре тәрбияләү кебек максатларны тормышка ашыру мөмкинлеге зур. Бу темаларның һәркайсына карата иртәләр-кичәләр үткәрергә була. Мәсәлән, безнең мәктәптә туган якны өйрәнү максатын тормышка ашырып: “Авылымда тарих эзләре”, “Авылым горурлыгым”, “Авылым матбугат битләрендә”, “Якташ язучыларыбыз”, “Сөйлим дисәм, сүзләрем күп...” кичәләре үткәрелде. Милли гореф-гадәтләр, йолаларны киләчәк буынга җиткерү максатыннан: “Халкымның күңел җәүһәрләре”, “Әбием сандыгы”, “Минем гаиләм - минем горурлыгым”, “Шушы яктан, шушы туфрактан без”, “Аулак өйдә”, “Нәүрүз бәйрәме”, һәм халкыбыз тарихын, үткәнен яктырткан әдәби әсәрләргә нигезләнеп әзерләнгән кичәләр дә үткәрелде. Халкыбызның авыз иҗаты күп төрле. “Табышмак әйтәм- җавап тап”, “Бәетләр һәм мөнәҗәтләр”, “Мәкальләрдә - халкым зирәклеге” исеме астында кичәләр үткәрү укучыларда намуслылык, гаделлек, хезмәт ярату, җаваплылык, тыйнаклык кебек уңай

сыйфатлар формалаштыруда, аң-белем бирүдә, халкыбызның зирәклегенә, тапкырлыгына тагын бер кат ышануга зур этәргеч булачак.

Тел дәресендә өйрәнелгән материалны ныгыту өчен төрле конкурс- бәйгеләр, викториналар үткәрү дә балаларны кызыксындыра, мондый ярышларда алар теләп катнашалар. “Туган телем- матур гөлем”, “Әткәм- әнкәмнең теле- минем туган телем”, “Туган тел җәүһәрләре”, “Антонимнар һәм синонимнар илендә” кичәләрендә сәнгатьле сөйләм, ярыш, конкурс, җыр-моң, уен төрләре кулланылды. Кызыклы биремнәр, табышмаклар, кроссвордлар, ребуслар, тестлар укучыларга компьютерда тәкъдим ителә.

Әдәби- музыкаль кичәләр, үз төбәгебездә яшәп иҗат итүче язучы-шагыйрьләр белән очрашулар, җирле һөнәрчеләр белән танышулар укучыларда туган ягыбызга мәхәббәт тәрбияли. “Шушы яктан, шушы туфрактан без”, “Авылымның урамын кабат-кабат урадым...” исемле кичәләр алда куелган максатларны тормышка ашыру максатыннан үткәрелде.

Дәресләрдән тыш тәрбия эшләре алып бару – балаларга төп белем бирүнең, аларны шәхес буларак үстерүнең аерылгысыз бер өлеше. Чыгарылыш квалификация эшебездә ана теле дәресләрендә дәрестән тыш чараларны куллану үзенчәлекләрен тикшереп, түбәндәге нәтиҗәләргә килдек.

1. Дәрестән тыш эш – дәрес кысаларына бикләнмәгән, әмма шул ук вакытта балаларның белемен да, зиһенен да үстерә торган, аларның, гамали шөгыльләренә, зәвыкларына, сәләт һәм мөмкинлекләренә уңай тәэсир иткән, әлеге файдалы чараларның һәммәсен ял һәм төрле уеннар белән бергә бик тә оста бәйли алган тәрбия эше. Мондый чараларны үткәрүдә укытучылар үзләре дә, ата-аналар да, башка оешма вәкилләре дә катнашырга мөмкин.

2. Ана теленә – туган телгә багышланган дәрестән тыш эшләр – белем һәм тәрбия эшенең аерылгысыз өлеше. Мәктәп һәр укучыны, булсын башлангыч, булсын өлкән сыйныф укучысын, сөйләм культурасына ия булырлык итеп тәрбияләргә, аңа туган тел турында тирән мәгълүмат бирергә бурычлы. Бу бурычны тормышка ашыруда, теоретик һәм методик яктан югары сыйфатлы дәресләр бирү белән беррәттән, дәрестән тыш эшләр дә укытучыга зур ярдәм итәләр. Укучыларны мәктәптә, сыйныфта чыгыш ясарга, моның өчен материалларны мөстәкыйль сайларга һәм әзерләргә өйрәтү, дәрестән тыш вакытта чишү өчен төрле башваткычлар, шарадалар, ребуслар уйлату, аларны төзетү, хәбәрчелек эшенә өйрәтү, телнең тарихы, телдәге аерым сүзләрнең һәм җөмләләрнең, сүзтезмәләрнең килеп чыгышы белән таныштыру – болар барысы да туган телгә мәхәббәт, иҗади актив шәхес тәрбияләүдә әһәмиятле чаралар.

3. Дәрестән тыш эшләрне уздырганда, тиешле методик принциплар күз уңында булырга тиеш. Беренчедән, дәрестән тыш эшләрдә катнашу-катнашмавын сайлауда укучы ирекле. Икенчедән, дәрестән тыш эшләрдә катнаштыру өчен, укучыларны яхшы яки начар укучыларга бүләргә ярамый. Укучыны, ничек укуына карамастан, дәрестән тыш эшләргә җәлеп итү мөһим, чөнки укытучының төп максаты – уку предметына кызыксыну тудыру. Өченчедән, дәрестән тыш эшләрне тел дәресләре белән органик рәвештә бәйләп алып барырга кирәк, бу очракта грамматиканың кагыйдәләр җыелмасы гына булмыйча, тел законнары турындагы кызыклы фән булуын укучыларга тирәнрәк һәм мавыктыргычрак итеп аңлатырга мөмкинлек туа.

4. Дәрестән тыш эшләр белем һәм тәрбия бирү мөмкинлекләре ягыннан тирән уйланылган, формасы ягыннан кызыклы һәм мавыктыргыч булырга тиеш. Дәресләр белән тыгыз бәйләнештә оештырылырга, әмма, алардан аермалы буларак, мөстәкыйльлек, иҗади активлык, материаллар күплеге белән аерылып торырга, бизәкле һәм эмоциональ итеп алып барылырга тиеш.

5. Сайланган эш төрләре, аларның максатлары һәм материаллары укучыларның яшь үзенчәлекләренә яраклы булсын. Дәрестән тыш эшләр мөмкин кадәр күбрәк укучы катнашында хәзерләнергә һәм оештырылырга тиеш.

6. Туган телгә багышлап дәрестән тыш эшләр уздыру җитди һәм катлаулы мәсьәлә булып тора. Дәрестән тыш эшләрне киң планда һәм максатка юнәлдереп алып бару өчен, укытучының үзеннән иҗади фикер йөртү һәм зур тырышлык сорала. Шунысын мөһим: укучы, активлыгын күрсәтеп, үзе өчен тәҗрибә туплап, үзенең талантын ача, аның үз-үзенә ышанычы арта, кеше арасында үз-үзен тотышы да камилләшә.

Гомумән, туган телгә багышлап үткәрелгән дәрестән тыш эшләр укучыларның активлыгын күтәрүгә, белем һәм культура дәрәҗәсен, сөйләм телләрен үстерүгә, дөньяга карашларын киңәйтүгә, аларны җәмәгать эшләренә җәлеп итәргә, матурлыкны аңларга өйрәтергә ярдәм итә. Тел турындагы кичәләр, атналыклар, айлыклар, олимпиадалар мәктәп балаларында бу фәнгә карата кызыксыну уяталар, алар ярдәмендә укучылар туган телнең нечкәлекләренә төшенәләр.

*Файдаланылган әдәбият*

*Норматив документлар:*

1. «Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында» Татарстан Республикасы Законы (2004 ел, 1 июль). Рәсми сайты:

http://tat.gossov.tatarstan.ru/dokument/pasport_zak/1992/1560_XII

2. «2004-2013 нче елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт программасы» (2004 ел, 11 октябрь). Рәсми сайты:

http://prav.tatarstan.ru/tat/docs/post/post1.htm?page=8&pub_id=314082

3. Татар урта мәктәпләре өчен әдәбият программалары. 5-11 нче сыйныфлар / Ф.Хатипов, А.Әхмәдуллин. − Казан, “Мәгариф”, 2005. 4. Татар телендә гомуми төп һәм урта белем бирү мәктәпләре өчен ана теленнән программа (5-9 нчы сыйныфлар). Төзүче-авторлары: Г.Р. Галиуллина, М.М. Шәкүрова. − Казан, 2013

*Методик һәм фәнни хезмәтләр*

Татар телендә:

1. Асылгәрәева Р.Ә. Бәйге камиллеккә чакыра.// Мәгариф. −2000. − №8. − 46-48 б.
2. Асылгәрәева Р.Ә. Урта мәктәптә татар телен укыту методикасы: Программа.– Казан: ТДГПУ, 2003. − 67 б.
3. Әминев А.Г., Әдһәмова Г.М. Урта мәктәптә әдәбият укыту методикасы. − Казан, Тат.кит. нәшрияты, 1977.
4. Әсәдуллин А.Ш. Рус телендә сөйләшүче балаларга татар теле укыту методикасы нигезләре / А.Ш.Әсәдуллин, Р.А. Юсупов. – Казан: Мәгариф, 1998. – 151 б.
5. Биктаһиров К., Галиуллин Т. Әдәбиятны ничек укытырга?. Мәгариф. − 2003. − №2.
6. Вагыйзов С.Г. Кызыклы грамматика: Укытучылар өчен кулланма / С.Г. Вагыйзов. – 3-нче басма, тулыл. – Казан: Мәгариф, 2002. – 207 б.
7. Вагыйзов С.Г., Вәлитова Р.Г. Башлангыч мәктәптә татар теле методикасы / С.Г.Вагыйзов, Р.Г.Вәлитова. – Казан: Мәгариф, 2003. – 415 б.
8. Вафин Ф. Татар теле атналыгы.// Мәгариф, 2005, №10, 89 бит.
9. Вәлиева Ф. Әдәп төбе − матур гадәт. // Мәгариф.−1999.− №10.− 73 б.
10. Вәлиева Ф. Татар теленнән класстан тыш эшләрне оештыру.// Мәгариф. −1999. − №11. − 40-42 б.
11. Вәлиева Ф. Туган тел кичәсе / Ф.Вәлиева. – Совет мәктәбе. – 1974. – № 6.
12. Вәлиева Ф.С. Урта мәктәп һәм гимназияләрдә татар телен укыту методикасы / Ф.С.Вәлиева, Г.Ф.Саттаров; ред. Р.Газизов; ф. ред. Г.Ф. Саттаров. – Казан: Раннур, 2000. – 455 б.

# СЫЙФАТ

*Сәлахова Ләйлә Шамил кызы,*
*“Тау Иле урта мәктәбе”, Мамадыш районы*

**Тема:** Сыйфат. (6 нчы сыйныф (татар төркеме) өчен татар теленнән дәрес эшкәртмәсе)

**Дәрес барышы**

1. Оештыру.

Укучыларның дәрескә әзерлеген тикшерү.

Укытучы өчен максат: балаларда яхшы кәеф, эшлисе килү халәте тудыру.

Укучылар өчен максат: дәрескә игътибар булдыру.

Укытучы: -Хәерле көн, укучылар!

-Кәефләрегез ничек? “Көнне яхшы сүз белән башласаң, бөтен көнең яхшы үтәр”,- диләр. Әйдәгез әле, бер-беребезне яңа көн белән котлыйк.

-Хәлләрегез ничек?

-Сез дәрескә әзерме?

Укучылар: -Хәерле көн, сезгә дә!

-Әйбәт.

-Сезне яңа көн белән котлыйбыз!

-Рәхмәт, әйбәт.

-Әйе, әзер.

2.Белемнәрне актуальләштерү

Өй эшен тикшерү.

Укытучы өчен максат: үткән теманы үзләштерү дәрәҗәләрен ачыклау.

Укучылар өчен максат: өй эше дөреслеген тикшерү.

-Сезгә өй эше нәрсә бирелгән иде? Эшли алдыгызмы?

-71 нче күнегү. Исемнәргә морфологик анализ ясарга, Туган ил турында мәкальләр алып килергә иде.

Морфологик анализ: Юл ташларына – исем, уртаклык, берлек санда, юнәлеш килешендә, 3нче зат тартым белән төрләнгән, тезмә исем, җөмләдә хәл. Аккошлар – исем, уртаклык, күплек санда, баш килештә, тартым белән төрләнмәгән, кушма исем, җөмләдә ия. Юлларның – исем, уртаклык, күплек санда, иялек килешендә, тартым белән төрләнмәгән, тамыр исем, җөмләдә тәмамлык.

-Яхшы, булдыргансыз.

- Ә хәзер үткән дәреснең темасын ныгыту максатыннан тест эшлибез.

Тест биремнәре (карточка бирелә).

1. Исем белдерә:

а) предмет яки затларны

б) предметларның исәбен яки билгесен

2. Ялгызлык исемнәр:

а) зур хәрефтән языла

б) кечкенә хәрефтән языла

3. Исемнәр ясалышы ягыннан ... төргә бүленә.

а) дүрт; б) алты

4. Тартым кушымчалары ярдәмендә ... белдерелә.

а) предметның кайсы затка караганлыгы

б) предметны эшләгән кеше

5.Килеш кушымчасы – кушымча.

а)бәйләүче

б) төрләндерүче

Тестны эшләү (бәяләү).

3.Уку мәсьәләсен кую.

1.Текст уку.

Күк йөзен соры болытлар каплаган. Көн дә яңгыр ява. Табигатьнең кәефе начар...

Менә берничә көннән соң бу ямьсез көннәр, матур кояшлы көннәр белән алышынды. Бик озак яуган яңгырлардан соң, коры көннәр башланды. Гүя табигатьнең чытык чырай белән яшисе килмәде, ахрысы. Бөтен җирдәге пычрак баткаклыклар көчле җил һәм көләч кояшның бердәм эшләве нәтиҗәсендә, бөтенләй булмагандай, кибеп бетте. Табигатьнең йөзе ачылганга, кешеләрнең йөзләрендә шатлыклы елмаю балкыды. Ни әйтсәң дә, тормыш ямьле шул.

-Текстта сүз нәрсә турында бара?

- Яңгырлар ява, ә аннан соң матур көннәр башлана.

-Димәк, җирдә һәр нәрсә чиратлаштырыла. Көннәр нинди генә булмасын һәр туган көнгә шатланып яшәргә кирәк!

-Нинди? соравына җавап биргән сүзләрне табабыз.

-Соры, начар, ямьсез, матур, кояшлы, коры, чытык, пычрак, көчле, көләч, шатлыклы, ямьле.

-Алар нәрсәләр?

-Сыйфатлар.

-Безнең дәресебезнең темасы нинди булыр?

- Үзебезгә нинди максатлар куярбыз икән?

-Сыйфат турында күбрәк белү; аны башка сүз төркемнәреннән аера белү; сөйләм төзүдә аларны куллану.

4.Уку мәсьәләсен чишү.

-Димәк, безнең бүгенге дәресебезнең темасы: “Сыйфат” булыр.(1 нче слайд)

-Ул нәрсәне белдерә?

-Предметның билгесен белдерә.

-Әйе, дөрес.

-Сораулары нинди?(2 нче слайд)

-Нинди? Кайсы? Кайдагы? Сорауларына җавап бирә.

-Әйе, слайдны карыйбыз.

-Сыйфат белдергән билгеләрне карыйк. (3 нче слайд)

1) Бирем: Һәр билгегә өчәр мисал әйтергә, дәфтәргә язарга.

1.Төсне белдергән сыйфатлар:

2.Тәмне:

3.Форманы:

4.Күләмне:

5.Физик сыйфатны:

6.Холкы:

7.Вакытка, урынга мөнәсәбәт:

1.Ак, кызыл, сары.

2.Тәмле, ачы, төче.

3.Түгәрәк, шакмак, озынча.

4.Зур, кечкенә, вак.

5.Кайнар, салкын, эссе.

6.Акыллы, усал, юаш.

7.Кичке, иртәнге, урмандагы.

-Яхшы, булдырдыгыз. Ә сыйфат ачыклаган сүз – сыйфатланмыш дип атала. Мисал китерик әле.

-Кызыл (сыйфат) алма (сыйфатланмыш).

-Хәзер ясалышы ягыннан сыйфатларның төрләрен белербез. 4 нче слайдны карыйбыз.

-Ясалышлары ягыннан сыйфатлар нинди була?

-Мисаллар китерәбез.

-Тамыр(ак), ясалма(аксыл), кушма(аккош), парлы(ап-ак), тезмә(ак төстәге).

2)Сыйфат дәрәҗәләре. 5нче слайдны карыйбыз. Ничә дәрәҗәсе бар?

-4 дәрәҗәсе бар.

-Гади (сары), чагыштыру(сарырак), артыклык(сап-сары), кимлек(саргылт).

-Әйе, дөрес. Алар белән җөмләләр төзибез.

-Чебиләр кечкенә чакта сары төстә була. Алсуның чәче Гөлнарныкына караганда сарырак. Күрше кызы сап-сары күлмәк кигән. Китапханәдән саргылт тышлы китап алдым.

- Бик яхшы.

-Сыйфат дәрәҗәләре нәрсә аңлата? -Аларны без ни өчен кулланабыз? --Алар булмаса безгә җөмлә төзергә җиңел булыр идеме?

-Җөмләләрнең мәгънә төсмерен үзгәртү өчен кирәк.

-Әйе, бик дөрес уйлыйсыз.

-Ә җөмләдә нинди җөмлә кисәкләре белән белдерелә икән?

-Аергыч, хәбәр, хәл.

6 нчы слайдны карыйбыз.

-Һәр очракка берәр мисал уйлыйбыз, тактада язабыз.

1. Бүген көн матур.(хәбәр)

2. Минем яңа күлмәгем бар.(аергыч).

3. Апа матур җырлый.(хәл)

3) Дәреслек белән эш.

-Хәзер дәреслекләрне ачабыз. 72 нче күнегүне карыйбыз. Сәнгатьле итеп укыйбыз. Сыйфатларны табып, аларга сораулар куябыз.

-Гүзәл, хуш исле, назлы,язгы, энҗе,иксез-чиксез, калын, матур, бәрәкәтле, уңайлы, уңдырышлы, мул сулы, кара, биек, көмеш сулы, гүзәл (нинди?).

-Яхшы, молодцы.

-75 нче күнегүне язмача эшлибез. Җөмләләргә сыйфатланмыш өстәп язарга.

4)Сыйфатларның исемләшүе. 7нче слайдны карыйбыз.

-Сыйфат кайсы очракта исемләшә?

-Сыйфат ачыклап килгән исем төшеп калса, сыйфатлар исемләшә.

-Мисаллар китерәбез: тактага карыйбыз, мәгънәләрнен аңлатабыз.

-Теле озынның акылы кыска. Теле татлының дусты күп. Эшлекленең эше бетәр, эшлексезнең көне үтәр. Инсафлының теле саф. Көчледән тау курыккан. Һөнәрле үлмәс, һөнәрсез көн күрмәс. - Батыр бернәрсәдән дә курыкмый. Карт капка төбенә чыгып утырды. Олыларны хөрмәт итәргә кирәк.Олыласаң олыны, олыларлар үзеңне.

5.Физкультминут.

-Әйдәгез, хәзер ял итеп алыйк.

Торып басабыз һәм музыкага биибез. (Татарча бию көе куела).

Музыка туктагач, сорауларга җавап бирергә кирәк булыр.

(Музыкага бию һәм сорауларга җавап бирү).

- Рәсемгә карап, нинди? соравына җавап биргән сүзләрне әйтергә.

- Сары, зур, йомшак.

- Чагыштыру дәрәҗәсендәге сыйфатны табыгыз.

- Матуррак.

- Исемнәргә сыйфатлар өстәгез: ... парта, ... ишек, ... кыңгырау, ... күлмәк.

- Уңайлы парта, ачык ишек, зур мәктәп, соңгы кыңгырау, яңа күлмәк.

6.Ныгыту.

- Яхшы, молодцы! Хәзер теманы ныгыту өчен иҗади диктант язабыз.

1)Иҗади диктант язу:Бу кем? Ул нинди?

1. Мәктәп җитәкчесе - ...

2. Поездда, трамвайда, автобуста баручы кеше - ...

3. Тәҗрибәле, сугышларда катнашкан кеше - ...

4. Спорт ярышларында җиңүче кеше - ...

5. Хор белән җитәкчелек итүче кеше - ...

6. Дәресләр арасы - ...

7. Ел вакытлары - ...

8. Халык авыз иҗаты - ...

- Директор –таләпчән, пассажир - намуслы, ветеран –хөрмәткә лаек, призёр- җитез, дирижёр-оста, тәнәфес- озын, кыш- салкын, фольклор- борынгы.

2) Карточкалар белән эш.

Бирем: Сыйфатларга сыйфатланмыш өстәп язарга, алар белән җөмлә төзергә.

Акыллы, җитди, таза, батыр, кирәкле, ачы, караңгы, йомшак, көмеш, ак, кайнар.

- Акыллы галим, җитди кеше, таза имән, батыр сугышчы, кирәкле эш, ачы балан, караңгы төн, йомшак мендәр, көмеш алка, ак кар, кайнар аш.

Безнең бакчада таза имән үсә. Муса Җәлил батыр сугышчы булган. Кирәкле эш эшләсәң, көн үткәне сизелми. Иң ахырда ачы балан өлгерә. Мин үземнең йомшак мендәремне яратам. Әти әнигә көмеш алка бүләк итте. Урамда ак кар ява, ә без өйдә кайнар аш ашыйбыз.

3)Рәсемнәр белән эш.

-Рәсемдә нәрсә сурәтләнгән? -Кышкы көн.



-Кышкы көн нинди? -Көн салкын түгел, матур.

-Балалар нишли? -Балалар уйный, чана шуа, кар атышлы уйныйлар.

-Балаларның кәефләре нинди? -Аларга күңелле.

-Ә бу рәсемдә нәрсә күрәбез? -Кыш. Кар ява. Бөтен җир ак.



-Балалар нәрсә ясыйлар? -Балалар Кар бабай ясыйлар.

-Кар бабай нинди? -Кар бабай зур һәм матур.

-Зур, матур, күңелле сүзләре нинди сүз төркемнәре булды?

-Сыйфатлар.

-Алар җөмләләрне нишләтә?

-Җөмләләрне матурлыйлар.

7. Рефлексия.

-Укучылар, бүген без дәрестә нишләдек?

- Сыйфатның предмет билгесен белдерүен, нинди? кайсы? кайдагы? сорауларына җавап бирүен, сыйфат ачыклаган исемнең сыйфатланмыш икәнлеген, җөмләдә күбесенчә аергыч, хәбәр һәм хәл булып килүен белдек.

-Нинди максат куйдык? Максатка ирештекме? Үзегез өчен яңалык булдымы?

-Нинди авырлыклар булды? Алдагы дәресләрдә дә белемнәрне тиешенчә куллана алырсызмы?

-Әйе, максатыбызга ирештек. Авырлыклар булды, ләкин без аларны чиштек.

8. Билге кую (үзбәя).

- Бүгенге дәрестә үзегезгә нинди билге куяр идегез?

“Мин барысын да аңладым, дустыма ярдәм итә алам” – “5”.

“Мин аңладым, эшли алам” – “4”.

“Мин аңладым, тик сорауларым калды” - “3”. (Укучылар үзләренә билге куялар).

9. Өй эше бирү.

1. 51 нче биттәге сорауларга җаваплар әзерләргә, 76 нчы күнегү сыйфатларны сыйфатланмышлары белән бергә язып алырга.

2. ”Кышкы көн” дигән темага кечкенә хикәя язарга. Хикәядә сыйфатларны мөмкин кадәр күбрәк кулланырга.

-Бүген алган белемнәрегезне киләчәктә куллана белерсез дип ышанам.

-Дәрестә актив катнашуыгыз өчен рәхмәт. Дәрес тәмам. Сау булыгыз.

## ЧТО ТАКОЕ СИММЕТРИЯ? ИЗДЕЛИЕ «БАБОЧКА»

*Сибгатова Фания Саубановна,*
*МБОУ «СОШ с.Манзарас», Кукморский район*

| **Тема** | Что такое симметрия? Как получить симметричные детали? Работа с бумагой . Изделие «Бабочка» ( 2класс) |
|---|---|
| **Цель темы** | Сформировать представление о новом способе работы с бумагой «симметричное вырезывание»,<br>Тренировать мыслительные операции: анализ, сравнение, умение действовать по установленному правилу; развивать внимание, мелкую моторику рук.<br>Воспитывать эстетические чувства, аккуратность, веру в свои силы. |
| **Планируемый результат** | Иметь представление о таком виде работы с бумагой как симметричное вырезывание.<br>Уметь выполнять детали из бумаги, используя способ «симметричного вырезания». |
| **Тип урока** | Открытие нового знания |
| **Основные понятия** | Понятия:<br>- симметричное вырезание<br>- ось симметрии |
| **Межпредметные связи** | Технология, математика, окружающий мир, экология |
| **Средства обучения** | **Учебники, учебные пособия**.<br><u>Для учителя:</u><br>- методические материалы, сопровождающие ФГОС НОО |

| | |
|---|---|
| | (примерная программа по технологии, планируемые результаты, оценка достижений планируемых результатов)<br>- УМК по технологии (программа, учебник, рабочая тетрадь, методические пособия и книги для учителя). |
| **Организация пространства** | Работа фронтальная, индивидуальная, в парах |

| **Этапы урока** | **Деятельность ученика** | **Деятельность учителя** | **Обучающие и развивающие задания каждого этапа** |
|---|---|---|---|
| **1. Мотивация к учебной деятельности** | Самоопределяются к учебной деятельности | Настраивает детей на работу, фиксирует на доске карточки двух шагов учебной деятельности. | - Ребята, прежде чем мы начнём с вами нашу работу, посмотрите друг на друга, улыбнитесь. Я рада видеть ваши улыбки. Пусть этот день принесёт вам радость общения.<br>-А начнём мы наш урок с загадки:<br>Спал цветок и вдруг проснулся<br>Больше спать не захотел.<br>Шевельнулся, встрепенулся,<br>Взвился вверх и улетел. (Бабочка.)<br>-Верно. Что вы знаете о бабочках? Поделитесь своими знаниями об этом насекомом друг с другом (по вариантам рассказывают друг другу).<br>Вслух рассказывает один ученик, остальные по желанию дополняют ответ.<br>-Я хочу вам сказать о том, что 2017 год в нашей республике был объявлен годом экологии. Кто знает, что такое экология? А как вы думаете, как взаимосвязаны между собой такие слова как экология и бабочка? ( Ответы ребят)<br>-Совершенно верно.<br>- А приходилось ли вам самим делать бабочку? (Да, нет.)<br>- Сегодня на уроке вы этому научитесь. Вспомните, какие шаги учебной деятельности вы должны выполнить? (Сами понять, что мы не знаем, и сами должны открыть новое.)<br>- С чего начнём свою |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | работу? (С повторения.) |
| **2 этап. Актуализация знаний и фиксация затруднения в пробном действии** | Анализируют информацию. Работая в парах, вспоминают и рассказывают друг другу правила соблюдения техники безопасности на уроках труда. Анализируют и выполняют пробное действие | Организовывает фронтальную работу учащихся, используя дидактическую карту по технологии. Проводит инструктаж по технике безопасности, организуя работу в парах. Даёт задание для выполнения пробного действия Фиксирует возникшую проблему у детей | - Сейчас мы с вами будем создавать бабочку. Посмотрите внимательно на дидактическую карту. Что понадобится нам на уроке? (Белая и цветная бумага, ножницы, карандаш.)<br>-Какие действия придётся совершить с бумагой, чтобы получить бабочку?<br>- Сегодня на уроке мы будем работать с ножницами, клеем. **Работая в парах**, вспомните и расскажите друг другу правила, которые необходимо соблюдать при работе с ножницами, с клеем.<br>**Задание для пробного действия.**<br>- Попробуйте получить сами бабочку без трафарета.<br>***Учащиеся самостоятельно пытаются получить изделие без трафарета.***<br>- Итак, покажите своих бабочек. Половинки бабочек одинаковые? (Нет.)<br>- Получилось выполнить задание? (Нет.) |
| **3 этап. Выявление места и причины затруднения.** | Восстанавливают выполненные операции и фиксируют в речи место, где возникло затруднение, анализируют и фиксируют в речи причину затруднения. | Организует выявление учащимися места и причины затруднения. | - Какое задание выполняли? (Мы должны были получить бабочку с одинаковыми половинками без трафарета, шаблона.)<br>- Каким способом пытались воспользоваться? (Мы рисовали бабочек, вырезали их.)<br>- Почему возникло затруднение? (У нас нет трафарета.)<br>- Значит, какого способа мы пока не знаем? (Как получить бабочку без трафарета.) |
| **4 этап. Построение проекта выхода из затруднения.** | Формулируют цель, тему урока; определяют способ выхода из затруднения. | Руководит работой учащихся по построению проекта выхода из затруднения. | - Какую цель мы поставим перед собой на уроке? (Узнать, как получить одинаковые детали без трафарета.)<br>- Сформулируйте тему нашего урока .<br>- Вспомним, что можно делать с бумагой? (Рвать, мять, |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | сгибать, склеить…)<br>- Попробуйте воспользоваться способом «сгибания бумаги». Согните бабочку пополам. Совпали её стороны? (Нет.)<br>- Нам необходимо, чтобы половинки были одинаковые и их стороны при сгибании по середине совпадали. |
| геоинформационные системы | проект путешествия |
| гномон | растения – индикаторы |
| график температур | река |
| гумус | рекреационный маршрут |

| | |
|---|---|
| квадрант | рельеф |
| кислотность почвы | родник |
| климат | роза ветров |
| масштаб | свойства воды |
| метеорология | синоптик |
| метеорологические наблюдения | среднесуточная и среднемесячная температура |
| метеорологическая станция | структура почвы |
| минералы | теллурий |
| методы изучения географии | топонимика |
| механический состав почвы | шарообразность Земли |
| направления | флюгер |
| объекты изучения географии | экологический маршрут |
| погода | экологическое состояние |
| | фенология |

*Литература, интернет-ресурсы*

1. Александрова В.П., Гусейнов А.Н., Нифантьева Е.А., Болгова И.В., Шапошникова И.А. Изучаем экологию города на примере московского столичного региона (пособие учителю по организации практических занятий)// М.: Издательство Бином. – 2009. 400 с., илл.

2. Архивные сведения о топонимике района (Архив Балтасинского района)

3. Летягин А.А. Дневник географа-следопыта/М.: издательский центр «Вентана-Граф». – 2013.96 с.. илл.: вкл

4. Мухамметшин Г.С. "Урбар" – Казань, 2013. – 720 с.

5. Тайсин А.С. География Республики Татарстан (учебное пособие для учащихся 8-9 классов средней школы) Казань, 2010.-246с.

6. Хуснутдинов А.А. "Схема территориального планирования Балтасинского муниципального района" – Казань, 2012 – 224 с.

5. Сайты Гидрометцентр России и Погода РБК.

## ДИНАСТИЯ ЛЕСОВОДОВ КАРИМУЛЛИНЫХ

*Шакирова Адиля Марселевна, 5 класс*
*Научный руководитель - Каримуллина Эндже Наилевна, МБОУ "Шумбутская СОШ", Рыбно-Слободский район*

Интересно, можно ли передать профессию по наследству? Такой вопрос возник у меня недавно, когда нам поручили написать дома сочинение про свою семью, про членов моей семьи, про их увлечения и профессию. И я задумалась о профессии моих родителей. Мой папа – учитель, мама работает библиотекарем, хотя и окончила лесной техникум, дедушка и бабушка со стороны матери – лесники, дядя и тетя также лесоводы. Так у меня возник еще один вопрос: а не суждено ли мне идти по их стопам?

Изучая различные исторические факты, я обратила внимание на то, что складываются династии педагогов, врачей, музыкантов и т.д. Издревле на Руси существовала традиция: представители одной семьи занимались одним видом деятельности. Так рождались династии.

Династия - череда людей, происходящих из одного рода, которые продолжают дела своих родителей, идут по их стопам. Подчас они выбирают одну дорогу в жизни, одну специальность, одно и то же учебное заведение, где когда-то учились и работали члены их

семьи. Что это? Ни наследственность ли? Вот именно на этот вопрос предстоит мне ответить в своей работе.

**Актуальность данной работы** заключается в том, что без крепкой счастливой семьи не будет крепкой страны. Проблема изучения преемственности семейной династии важна и актуальна как никогда в настоящее время. Мне кажется, будущее возможно только там, где помнят своих предков, где уважают старших. Мне всего лишь 12 лет, но мне очень интересно, как у нас возникла династия лесоводов, кто стоит в начале династии. Итак, в данной работе я расскажу о своих родных и близких людях.

**Цель исследования**: собрать материал для составления данных о династии моей семьи Каримуллиных.

Для достижения своей цели я поставила перед собой следующие **задачи**:

знакомство с историей создания и развития моей семьи;

сформировать представления о семье, профессии родителей.

**Объектом исследования** является семья Каримуллиных, поскольку многие представители этой семьи имеют отношение к лесоводству.

**Предметом исследования** является процесс изучения исторических источников, фотографий, статей, газет, видео.

**Методы исследования**: метод сравнительного анализа, количественный метод, интервью, анкетирование, историко-системный метод.

**Гипотеза:**

Существует гипотеза, что выбор профессии зависит от чувств, мыслей, заложенных в человека еще в детстве. А при передаче детям своей профессии, своего дела, любви к своей профессии – это самый надёжный способ сохранить преемственность поколений, способ создать династию. Нам кажется, только так рождаются династии врачей, учителей, спортсменов, лесоводов.

Данной работой я хочу показать истинную картину преемственности поколений на примере своих родственников, семьи Каримуллиных и Мукминовых. Я считаю, что эти люди являются настоящими профессионалами своего дела, любящими свою профессию и полностью отдающими себя ей.

**План моей работы:**

1. Изучить родословную.
2. Опросить бабушку, родителей, близких родственников и записать результаты опроса.
3. Оцифровать фотографии из семейных альбомов.
4. Занести собранную информацию на электронный носитель.

**Основная часть.**

***Родоначальник династии.***

Все началось в далеком прошлом. В 1947 году мой прадед Каримуллин Габдулла Каримуллович вернулся с войны и решил, что никогда больше не покинет родную землю, родную деревню. Он устроился лесорубом в местное лесничество, но трудолюбивого, ответственного молодого человека быстро заметили и уговорили выучиться. Так в 1949 году прадедушка, окончив курсы по лесничеству, был принят лесником в Кзыл-Юлдузское лесничество Камского леспромхоза. Всю свою жизнь прадед посвятил лесу, до 1986 года, то есть до самой пенсии, он проработал в лесничестве. Он гордился, что всю жизнь работал на одном месте, зато и лесное хозяйство он знал, как свои пять пальцев. Поэтому к нему обращались за советом, даже после того как он ушел на пенсию.

За всю жизнь мой прадедушка получил много почетных грамот и благодарственных писем, а самая большая награда – это вечнозеленый хвойный лес, который растет вокруг нашей деревни, это благодарность людей, которым помогал мой дед на протяжении своей жизни.

***Второе поколение Каримуллиных.***

Мой дед, Каримуллин Мансур Габдуллович, родился в 1953 году в посёлке Шестая речка Рыбно-Слободского района в семье лесника. У своего отца (моего прадеда) он научился бережно относиться к природе. С детства дедушка запомнил, что нельзя в лесу оставлять непотушенным костер, что после привала нужно очистить от мусора поляну, и, наверное, поэтому уже тогда он понял, что его будущая профессия будет связана с лесом. Окончив школу, дедушка несколько лет проработал в бригаде своего отца, позже был призван в ряды Советской армии. Вернувшись с армии и познакомившись с моей будущей бабушкой, на тот момент работающей помощником в Приволжском лесхозе, дед окончательно решил выучиться на лесника. И в 1977 году он поступает в Лубянский лесхоз-техникум и удачно его заканчивает. В1980 году назначен лесничим Чулпанихинского лесничества Приволжского лесхоза.

Самое время рассказать про мою бабушку. Моя бабушка, Каримуллина (до замужества Мукминова) Рашида Гимадеевна, родилась в 1954 году, после окончания школы в 1969 поступила на обучение в Лубянский лесхоз-техникум. В 1973 году после удачной практики и окончания техникума была направлена в Лебяжеский лесхоз Курганской области, где работала экономистом лесного хозяйства. Отработав положенные три года, в 1976 она переводом вернулась в родной Татарстан и устроилась на работу в Приволжский лесхоз помощником лесничего.

В 1976 году бабушка выходит замуж за моего будущего деда, и вместе они начинают трудиться во благо Родины, во благо возрождения лесов.

***Третье поколение Каримуллиных.***

Я думаю русская народная пословица «Яблоко от яблони недалеко падает» как нельзя лучше подходит к нашей семье. Мои бабушка и дедушка вырастили и воспитали троих детей. По словам моей мамы, они с самого детства видели, как бабушка с дедушкой уважительно и заботливо относились к лесу, как ответственно подходили к своей работе. Видя какое удовольствие получают их родители от своей работы, мама и её сестра не могли не выбрать эту профессию. Так, в 1994 году после окончания школы моя тетя, Каримуллина (сейчас Шафикова) Гульназ Мансуровна, поступает на учёбу в Лубянский лесхоз-техникум по специальности «Бухгалтер лесного хозяйства», по окончании которого она устраивается на работу бухгалтером в Шумбутское лесничество. После замужества тётя перевелась в Кутлу-Букашское лесничество, где уже проработала более 15 лет.

Моя мама, Шакирова (до замужества Каримуллина) Гульшат Мансуровна после окончания школы недолго выбирала свою будущую профессию и учебное заведение, она уже с 5 класса знала, что обязательно продолжит дело своих родителей. Окончив школу и сдав экзамены, она поступила в Лубянский лесхоз-техникум. После окончания техникума мама вышла замуж за моего папу и переехала в деревню. Здесь она несколько лет проработала в Шумбутском лесничестве, но по воле судьбы так получилось, что сейчас она работает в сельской библиотеке. Она говорит, что смена места работы никак не повлияла на любовь к лесу. Она уверена, что такая любовь передается от поколения к поколению и тот, кто пришел в эту профессию, никогда не сможет ее забыть

По стопам своих родителей пошел и мой дядя, Каримуллин Ильнар Мансурович. После окончания средней школы, в 2001 году он поступил учиться в Лубянский лесхоз-техникум. Успешно окончив его и получив диплом техника леса, мой дядя был принят на работу в Прикамское лесничество Камского леспромхоза в качестве мастер леса. Мой дядя Ильнар говорит, что если человек выбирает столь нужную профессию, то он должен обладать большим чувством ответственности, а главное - любовью. Любовью к природе. Это очень важно, потому что от этого зависит жизнь не только животных, растений, но и жизнь всего человечества.

Совместный трудовой стаж семьи Каримуллиных в лесоводстве получается более 100 лет. Я очень горжусь, что родилась в этой семье! Я могу твердо сказать, что люди, о которых я рассказала, династия Каримуллиных – прекрасный пример для многих.

***Ветвь Мукминовых***

Родная сестра моей бабушки, Мукминова (сейчас Кузнецова) Минслу Гимадеевна, в 1975 году окончила Лубянский лесхоз-техникум. Она была направлена на работу в качестве техника-лесовода в Ильинский лесхоз Пермской области. Очно окончила Институт лесного хозяйства города Свердловска, где познакомилась со своим будущим мужем Алексеем Александровичем. После окончания института тётя уезжает с мужем в Нижегородскую область, где до 2015 года проработала главным экологом лесного хозяйства Уреньского района. А дядя наш, Алексей Александрович, стал заслуженным лесоводом. И несмотря на то что он уже на пенсии, все еще он работает лесником, он остается преданным своему делу.

**Заключение**

Работая над данным проектом, я узнала много интересного о своей семье и ее истории, о профессиях в жизни моей семьи.

Я горжусь, что родилась именно в этой семье, где всегда царит любовь, взаимоуважение, где ценятся семейные традиции, где молодежь почитает мнение старших.

Проанализировав весь собранный материал, я могу сделать вывод, что для каждого человека, о котором я рассказала, лесоводство - это не просто профессия, это еще и жизнь, и судьба, и призвание. И я знаю: примером профессионализма, верности своей профессии для меня будут герои моей исследовательской работы. Кем я стану, когда окончу школу, я ещё не знаю, мне кажется, у меня для этого еще есть время. Но одно я знаю точно, что постараюсь быть достойным представителем моей большой семьи.

Моя семья – это прекрасный пример преемственности поколений.

Закончить свое выступления я хочу стихотворением Ирины Веренчик.

Династия — гордое слово!
Сплелись поколения в нём.
Мы славу труда наших предков
Достойно сквозь годы несём.

Не просто несём — умножаем.
Их труд путеводной звездой
С потомками в ногу шагая,
Стал в жизни желанной судьбой!

Потомственный врач иль учитель.
Как славно и громко звучит!
И в русле семейного счастья
Дух единенья кипит.

Во славу единого дела
Они на Земле родились.
Секреты и опыт, и знания
В наследство передались.

Так пусть же растут, процветают
На благо огромной страны.
Ведь трудовые династии
Бесспорно, нужны и важны

*Список использованной литературы*

1. В.И. Самаркина. Нет России без леса. Нижний Новгород. Издательство «Штрих», 2000.

2. Детский экологический журнал для чтения в кругу семьи и в школе. «Свирель», 2008год.

# ДӘҮ ӘТИЕМ – МИНЕМ ГОРУРЛЫГЫМ

*Шакирова Инзилә Алмаз кызы, 3 сыйныф*
*Фәнни җитәкче - Муллагалиева Зөлфия Гомәр кызы,*
*Әтнә районы МБГББУ "Олы Мәңгәр төп гомуми белем бирү мәктәбе"*

Һәр төбәкнең бик матур кешеләре бар. Төскә – биткә генә түгел, үзләренең күркәм эшләре, тоткан кыйблалары белән киләчәк буыннарга үзләреннән тирән эз калдырган шәхесләр яши. Алар мактанып йөрмиләр, тыныч кына хезмәт итәләр.

Авылыбызда хөрмәт итәрлек, һәрвакыт истә тотарлык, олыларлык кешеләр байтак. Минем дәү әтием – Шакиров Илсур Гариф улы да әнә шундыйларның берсе. Минем дәү әтием турында, аның балачагы, үсмерчагы турында күбрәк беләсем килде. Шулай итеп проек эшенең темасы сайланды.

Максат:

- дәү әтием турында күбрәк белү, аның тормыш юлы белән танышу;
- дәү әтиемнең эшчәнлеген, аның яшәү рәвешен өйрәнеп, үземне аның шәхси үрнәгендә тәрбияләү;
- горурлык хисләрен үстерү, төрле буын кешеләрен якынайту;

Проект эшенең бурычлары:

- темага кагылышлы материал туплау, гаиләбезнең өлкән буыннары турында мәгълүматларны барлау;
- гаилә архивын өйрәнү;
- тупланган материалларны анализлап, нәтиҗәләр ясау.

Проект эшенең объекты – Шакиров Илсур Гариф улы.

Эшне башкару процессында мин кулланган методлар – интервью алу, гаилә архивы материалларын өйрәнү, чыганаклардан информация туплау.

Проект эшенең актуальлеге:

Үткәнен белмәгән кешенең киләчәге юк.

<u>Төп өлеш</u>

Минем дәү әтием Шакиров Илсур Гариф улы Бөек Ватан сугышы башланырга бер ай кала, 1941елның 23 нче маенда, колхозчы гаиләсендә дүртенче бала булып дөньяга килгән. Туып ике ай үтүгә аның әтисен сугышка алганнар. Дүрт бала, авыру әби – бабай әнисе карамагында калганнар.

Сугыш ятиме дәү әтигә, ул вакыттагы барлык балалар кебек ачлы – туклы яшәргә, черек бәрәңге, чыпчык кузгалагы, ашарга яраклы үләннәр белән тукланырга туры килгән. "Безнең балачак булмады, аны сугыш урлады. Без туйганчы уйный,туйганчы ашый-эчә алмадык. Кигән киемебез кырык ямаулы.Кар эреп, көз көне яңасы яуганчы яланаяк йөрелде, табан аслары катып машина протекторына әйләнә. Яз, көз, кыш көннәрендә аякта– чабата, күтәртмәле башмак",- дип искә төшерә дәү әтием.

Азрак үсә төшкәч ул авыр эшкә җигелгән. Терлекләргә печән җыйнау, мичкә ягу өчен сыер тизәген вакланган салам белән бутавы, кирпеч сугу, бәрәңге бакчасында эшләү балалар өстендә булган. Балаларның туйганчы уйнарга, су коенырга, балык тотарга да вакытлары калмаган.

Әнисе тырышлыгы белән дәү әтием үскән, фанера тактага дәреслекләрен салып беренче сыйныфка укырга кергән. Тырышып укыган.

1959 елда мәктәпне "4 - 5" билгеләренә тәмамлап Казан Дәүләт университетына укырга кергән. Аны 1965 елда уңышлы тәмамлап, Кемерово шәһәренә эшкә җибәрелгән. Ярты ел эшләгәч аны Совет Армиясенә хезмәт итәргә җибәргәннәр, офицер булырга укытканнар. Себер якларында дәү әтием Ватан алдында үз бурычын үти.

Армиядән кайткач, дәү әтием үзенең гомерен балалар укытуга багышлаган. Тукай – Кырлай, Пошалым мәктәпләрендә укытучы булып эшләгән. 1966 нчы елда дәү әнием белән

тормыш корып җибәрә. Ләкин язмыш аны тагын 2 елга гаиләсеннән аера. Ул Казахстан далаларында армиядә офицер булып хезмәт итә.

Туган мәктәбенә кайтып, 2008 нче елга кадәр хәрби хәзерлек укытучысы, химия укытучысы, директор урынбасары, мәктәп директоры булып эшләгән. Әти-әниләр сөйләве буенча ул балаларны яраткан, укучылар да аны хөрмәт иткәннәр. Гомернең 40 елын дәү әтием балаларга багышлый. Дәү әтием бик тырыш, туры сүзле, үз сүзендә нык торучы, киң күңелле педагог булган. Дәү әтием биргән химия фәне буенча, белемнәрне тирән үзләштереп, күп укучысы шул ук юлны сайлады. Ул тырыш хезмәте өчен "За успехи в образовании" значогы белән бүләкләнә. Хәзерге мәктәп директоры да Мухаметшина Гөлия Наил кызы, минем дәү әтиемнең укучысы, химия фәнен укыта. "Илсур абый "аяклы энциклопедия" кебек. Ул бүген дә нинди генә сорау белән мөрәҗәгать итсәк тә, ярдәмгә ашыга, белгәннәре белән уртаклаша. Үзенең туган мәктәбен онытмый", - дип әйтә дәү әтием турында аның укучысы.

Минем дәү әтиемнең хоббие бар. Ул рәсем ясарга ярата. Мәктәптә эшләгәндә ул укыту кабинетлары, мәктәп коридорлары, ашханә стеналарын бик матур рәсемнәр ясап бизәгән. Кызганычка каршы, моннан өч ел элек мәктәпкә капиталь ремонт ясаганда, дәү әтием истәлеге булган бу матур рәсемнәр юкка чыктылар. Дәү әтием табигатькә гашыйк кеше. Авылыбызның табигатен ул картиналарда күрсәтә. Бүгенге көндә ул ясаган егермеләп картина безнең йортыбызның стеналарын бизәп торалар.

Ул мәктәп музеен булдыру, аңа экспонатлар туплау, музейны бизәү буенча да күп эш башкарган. Бу музей әле дә дәү әти истәлеге булып тора, укучыларга тәрбия бирү урыны булып хезмәт итә.

Лаеклы ялга чыкканнан соң дәү әти туган авылыбыз тарихы, авылның күренекле шәхесләре, колхоз тормышы белән бәйле материаллар туплау белән мавыгып китте. Бу материалларны ул районыбыз газетасы "Әтнә таңы"нда, республикабыз газетасы "Татарстан яшьләре"ндә бастырып килде, газета укучыларының яраткан журналистына әйләнде. Үзенең күп санлы язмаларын туплап, дәү әтием авылыбыз тарихына багышланган "Авылым Олы Мәңгәр" һәм "Меңнәр иле Олы Мәңгәр" дигән күләмле ике китап бастырып авылдашларының тирән ихтирамын казанды. Ул әле дә авыл, әхлак темаларына мәкаләләр язуын дәвам итә.

Дәү әтиемнең тагын бер хоббие – яшелчә бакчасы. Ул – бакчачы. Җиләк – җимешләр,чәчәкләр үстерергә ярата. Мин дә дәү әтием янында еш булам бакчада. Дәү әтием мине тырышлыкка өйрәтә. "Бакча тырышны ярата. Шунсыз бакчадан уңыш алып булмый",- дип ярата кабатларга дәү әтием. Ошанмассыз, үстерү генә түгел, шул яшелчәләрне кышка әзерләү дә дәү әтиемнең иң яраткан эшләренең берсе. Ул тозлаган кыяр, томат, кәбестә тел йотарлык тәмле була.

Дәү әтием дәү әниебез Илсияр белән бергә 50 ел гомер иткәннәр, 3 бала ( 2 кыз, 1 малай ,төпчеге минем әтием – Алмаз) тәрбияләп үстергәннәр.

Хәзерге вакытта без дәү әтием һәм дәү әнием белән бергә бер гаилә булып яшибез. Бүген аларның 8 оныгы, 1 оныгының балалары бар. Аларның һәрберсенә аерым мөнәсәбәт. Дәү әтиемнән бервакытта да тупас сүзләр ишетмисең. Минем дәү әтием – үз янына балаларын һәм оныкларын җыеп, гаилә учагын саклаучы.

Дәү әти үзенең оныкларын, ягъни безне бик ярата. Иртән уңышлар теләп безне мәктәпкә озата, елмаеп каршы ала. Мәктәп хәлләре белән кызыксына. Бик теләп безгә дәрес хәзерләргә булыша.

Мин шундый дәү әтием булу белән горурланам, үзем дә аңа охшарга тырышам. Дәү әтиемә озын гомер телим.

Йомгаклау

Сүземне йомгаклап, шуны әйтәсем килә: без үз Туган ягыбызны,аның тарихын ныграк өйрәнсәк, аның киләчәге турында да тирәнрәк уйланырбыз дигән нигез бар. Бүгенге матур тормышта яшәвебез белән без аяклы тарихыбыз булган әби- бабаларыбызга мәңге бурычлы дип саныйм мин. Чөнки туган-тумача,кардәш-ыруга карата кайгыртучан

мөнәсәбәтне,туып-үскән җиребезгә тирән мәхәббәтне безнең өлкән буын бабаларыбыз яшь буынга мирас итеп калдырган һәм аларның бу тәрбиясен буыннан-буынга тапшыру безнең кулларда! Кешеләргә карата мәрхәмәтле булсак,әти-әниләребезне хөрмәт итеп тәрбия кылсак,милләтебез өчен файдалы эшләр башкарсак, бабаларыбызның изге туфрагын кадерләп сакласак - тормышыбыз матур һәм мәгънәле булыр. Дөньяга туган һәр сабый үзенең нәселе,ерак бабалары, гаиләсе белән горурланып яшәрлек булсын иде! Иң мөһиме,минемчә,үз артыңнан матур истәлекләр,тормышыңның якты мизгелләрен бүләк итеп калдыру!

*Файдаланылган әдәбият*

1.Шакиров И. “Авылым Олы Мәңгәр”, Казан, “Яз” нәшрияты, 2016.

2.Шакиров И. “Меңнәр иле Олы Мәңгәр”, Казан, “Яз” нәшрияты, 2017.

3. Гаилә архивы.

## ТОТАШКАН САВЫТЛАР

*Шарафиева Резеда Рифхатовна,*
*“Ядегәр урта гомуми белем бирү мәктәбе”*
*Кукмара районы*

**Тема: “Тоташкан савытлар” (**7 сыйныфта физика дәресе**)**

УМК: Перышкин А.В. Физика-7 – М.: Дрофа, 2006.

**Дәреснең максаты**: тоташкан савытлар биллгеләмәсен, бериш һәм бериш булмаган сыеклыклар өчен тигезләнеш шартын өйрәтү.

**Дәреснең бурычлары:**

**Белем алу:** тоташкан савытлар өчен сыекллыкларның тигезләнешен аңлатканда физик зурлыкларны дөрес кулланырга, тигезләнеш шартын куллануга мисаллар китерергә өйрәтү.

Үстерешле: классификациләү һәм гомумиләштерү, мөстәкыйль уйлау, нәтиҗәләр чыгару, эксперименталь эш күнекмәләрен үстерү.

Тәрбияви: үзара иптәшләрчә ярдәмләшү хисләре, группада эшләү этикасы тәрбияләү.

Планлаштырылган нәтиҗәләр:

Шәхси: башкаларга, аларның фикеренә аңлы дустанә караш, укуга аңлы мотвация.

Предметара: үзеңә белем алу максатлары куя һәм шул максат нигезендә эшли белү, эффектив белем алу юлларын табу, фәннәрнең үзара бәйләнешен күрү.

Предмет: табигать күренешләренең физик эчтәлеген күрү, аларны күзәтү, эксперементлар эшли белү, аларга нәтиҗә чыгару, тоташкан савытлар, аларның кулланылышы һәм төрләре турында күзаллау.

Төп төшенчәләр: тоташкан савытларда сыеклыклар тигезләнеше законы, шлюз, акведук.

Дәрес тибы: яңа белемнәр өйрәнү.

Ресурслар: дәреслек, презентация, формула язылган битләр, “Тоташкан савытлар” темасы буенча 4 вариант тест, экспериментларның максаты язылган, критерийлар язылган битләр, эксперимент өчен тоташкан савытларга мисаллар, динамик, үзбәя.

Предметара бәйләнеш: тарих, география, биология.

**Дәрес планы:**

**1. Мотивация этабы. Оештыру өлеше.**

**Максат:** Укучыларны эшкә әзерләү: эшкә җәлеп итәрлек шартлаар тудыру; балаларны бергәләп эшләүгә психологик яктан әзерләү.

**Коммуникатив УУГ**: үз-үзеңне тоту һәм аралашу; кагыйдәләре турында үзара килешү һәм аларны үтәү, үз фикереңне телдән формалаштыру.

**Укытучы:** - Исәнмесез, укучылар! Утырыгыз. Әйдәгез, таныш булыйк. Бүген дәресне мин, Шарафиева Резеда Рифхатовна, алып барачакмын. Сезнең белән беренче тапкыр гына очрашсак та сезнең белән дуслашырбыз дип ышанам.

**2. Проблема кую.**

**Максат:** тирә-юньдәге сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен күрә белергә өйрәтү;

тирә-юньне өйрәнергә мөмкин булуына төшендерү.

*Танып-белү:* Үз белемең системасында орентлаша белү (яңаны инде таныш булганыннан укытучы ярдәмендә аера алу, информацияне бер формадан икенчесенә күчерү);

Укытучы: - Слайдлардагы рәсемнәргә күз салыгыз. Рәсемнәрне предметларны ике группага аерыгыз. Нәрсәгә нигезләнүегезне аңлатыгыз.

Укучылар: Рәсемдәге предметларны 2 группага бүләләр, сәбәбен аңлаталар.

**3. Яңа белемнәр ачу.**

**Максат:** Укучыларның экспериментлар үткәрү; группада эшләү күнекмәләрен үстерү эшен дәвам итү; классификацияләү һәм гомумиләштерү; өйрәнелгән материал буенча нәтиҗәләр чыгару; мөстәкыйль уйлау һәм интеллектны үстерү; дөрес телдән сөйләм күнекмәләрен үстерү; экспериментль эш күнекмәләрен үстерү.

Укучыларга әхлак тәрбиясе: үзара иптәшләрчә ярдәмләшү хисләре; группада эшләү этикасы бирү.

*Коммуникатив:* Башкаларныың сөйләгәнен тыңлый һәм аңлый белү; үз фикереңне тулы һәм төгәл итеп телдән һәм язмача аңлата белү; үз фикереңне һәм позицияңне исбатлый белү.

***Көйләгеч (регулятив):*** Дәрес вакытында үзеңнең фикереңне, эш тәртибеңне телдән аңлата белү; беренчел уку эшчәнлеге вакытында үзеңә авыр булган очракларны күрә алу; уку максатын формалаштыра белергә, соңгы нәтиҗәне исәпкә алып арадаш максатлар эзлеклелеген табарга.

**Коммуникатив:** үз фикереңне җитәрлек дәрәҗәдә тулы һәм төгәл итеп аңлата белергә.

**Укытучы:** Тоташкан савытларга билгеләмә биреп карыйк:

**Укучылар:** Үзара сыеклык йөри алырлык итеп тоташтырылган савытларны тоташкан савытлар дип атыйлар.

**Укытучы.** Тоташкан савытлар шуның белән уңайлы. Аның берсенә салынган сыеклык шунда ук икенчесенә дә күчә.

-Сезнең алда тоташкан савыт- үзара резин трубка белән тоташкан ике пыяла көпшә. Аның уртасы кыстыргыч белән ябып куелган, икенче гына сыеклык салынган. Әгәр кыстыргычны алсак нәрсә күзәтелер? ***Укучылар үз фикерләрен әйтә.***

**Укытучы.(кытыргычны ача) әгәр трубканың берсен авыштырсам нәрсә булыр?**

**Укытучы.** Әгәр трубкаларның берсенә май салсак нәрсә булыр? Әгәр трубкаларның берсенең башын бөке белән томаласам нәрсә булыр? Әйдәгез, бергәләп тоташкан савытларда сыеклыкның тигезләнеш шартын чыгарыйк.

***Укучылар группаларда биремнәрне эшлиләр, нәтиҗә чыгарып битләргә язалар.***

*Биремнәр :*

**1 группа.** Тоташкан савытларга су салыгыз һәм көпшәләрне төрле якларга авыштырып карагыз. Су тынычлангач, өслеге ничек урнаша?

**Укучылар:**

- *Әгәр тоташкан савытларны төрле якларга авыштырсак, савыттагы сыеклык тынычлангач, ике көпшәдәге сыеклык өслекләре тигезләнә.*
- *Тоташкан савытларда бериш сыеклыкның ачык өслекләре бер үк биеклектә урнаша.*

**2 группа.** Төрле формадагы тоташкан савытка су салыгыз. Су тынычлангач, савытлардагы су өслеге ничек урнаша?

- *Теләсә нинди формадагы һәм кисемдәге тоташкан савытлар эчендәге бер үк биеклектә урнаша.*

**3 группа.** Тоташкан савытларның бер тармагына су, икенчесенә май салыгыз. Сыеклыклар тынычлангач, өслекләре ничек урнаша?

• *Савыттагы сыеклыкларның тыгызлыклары төрле, шунлыктан басымнары да төрле;*

• *Басымнар тигез булганда, тыгызлыгыы зуррак булган сыеклык баганасы тыгызлыгы азрак булган сыеклык баганасыннан кечерәк булыр.*

**Укытучы:**Исбатлыйк: тоташкан савытлар законы буенча, $p_1=p_2$, ә $p_1=g\rho_1h_1$, $p_2=g\rho_2h_2$ , $g\rho_1h_1=g\rho_2h_2$, ягъни $h_1:h_2=\rho_2:\rho_1$. Тыгызлыгы зуррак булган сыеклык баганасы, тыгызлыгы азрак булган сыеклык баганасыннан кечерәк була, ә аларның биеклекләре тыгызлыклар чагыштырмасына кире пропорциональ.

**4группа.**Әгәр тоташкан савытларның бер башын томалап су салсак, нәрсә күзәтелә?

- *Томаланган ягында су баганасы кечкенәрәк;*

- *Томаланган ягында эчтә калган һава суга күтәрелергә ирек бирми.*

- *Әгәр сыеклык өстендәге басым тигез булса, тоташкан савытларда тикторыш халәтендәге бериш сыеклык өслеге тигезләнеш хәлендә була.*

**5 группа.**Төрле юанлыктагы савытлардан торган тоташкан савытка су салсак, нәрсә күзәтелә?

*Киң өслекле савытларда су өсте тигезләнә. Савыт нечкәрәк булган саен су баганасының күтәрелү биеклеге зуррак.*

**Укытучы.** Соңгы очракта без тоташкан савытлар турында законның үтәлмәгән очракларын күрдек. Димәк, һәр физик законның да кулланылу чиге бар икәненә тагын бер кат ышанырга була. Соңгы очракта күзәтелгән күренешне капилляр күренешләр дип атыйлар. Аны үсемлекләрнең җирдән кирәкле микроэлементлар суыруында, кешенең кан системасында күзәтергә мөмкин. Бу очраклар инде чылану күренеше белән бәйле. Бу күренеш белән ныклабрак өлкән сыйныфларда танышырсыз.

Ә хәзер күзәтүләргә **нәтиҗә** ясыйк:

-Теләсә нинди формадагы һәм кисемдәге тоташкан савытлар эчендәге бериш сыеклыкның ачык өслекләре бертигез биеклектә урнаша.

- Басымнар тигез булганда, тыгызлыгы зуррак булган сыеклык баганасы тыгызлыгы азрак булган сыеклык баганасыннан кечерәк булыр.

4. **Беренчел ныгыту.**

**Максат:** Укучыларның информация чыганакларын анализлау күнекмәләрен үстерү.

*Танып-белү:*яңа белемнәр алу (дәреслек, үз тормыш тәҗрибәң һәм дәрестә алган информация ярдәмендә сорауларга җавап табу);

*Коммуникатив:* Үз фикереңне тулы һәм төгәл итеп телдән аңлата белү; башкаларнының сөйләгәнен тыңлый һәм аңлый белү, үз фикереңне тулы һәм төгәл итеп телдән һәм язма рәвештә аңлата белү, башкаларның сөйләмен тыңлый һәм аңлый белү.

***Көйләгеч (регулятив):***Коллектив рәвештә төзелгән план буенча эшләү, дәрес вакытында үзеңнең эш тәртибеңне телдән аңлата белү;

**Укытучы:**Рәсемгә карагыз. Бу очракны кайларда кулланып була?

**Укытучы:** Әйдәгез, фонтаннар турында **видеосюжет** карап китик. Безнең илдә иң өлкән фонтаннар булып Санкт-Петербург шәһәрендәге Петергоф фонтаннары тора. Петр баштарак кечкенә фонтаннар каскады гына төзергә тели. 1720 нче елда Ропшин калкулыгында су чыганаклары табыла. Аннан киңлеге 6, тирәнлеге 2 м, озынлыгы 24 км булган канал төзелә башлый. Бу сууткәргечнең төзүчесе беренче инженер гидравлик В.Туволков була. Бу каналны эшләүдә көн саен 2 шәр меңнән артык кеше катнаша. Баштагы агач трубалар бик тиз череп эштән чыкканлыктан, чуен торбалар кулланыла. Бу каналлар буйлап су Ропшин калкулыгыннан үз агымы белән Петр сараеның Югары бакчаларына килә. Монда фонтаннар биек булмаса да, Түбән парк аннан 16 м га түбәндәрәк булганлыктан, фонтаннар тагын да биеккә күтәрелә. Алар, туры Диңгез каналы аша Фин култыгына агып төшә. Күпләр Петр сараеның фонтаннары насослар ярдәмендә эшли дип уйлыйлар. Чөнки Франциянең атаклы Версаль сарае фонтаннары насосларны эшләтү бик кыйбатка төшкәнлектән, атнага 2 көн 2 шәр сәгать кенә эшлиләр. Ә Петергофта фонтаннарны җәй көне тәүлек әйләнәсе күзәтергә була.

Безнең башкалабыз Казанда да фонтаннар күп. Г. Камал театры каршындагыларын җырлаучы фонтаннар дип йөртәләр. Аларның агымы музыка ритмына көйләнә. “Су анасы”фонтаны Бауман урамына куелган. Исеменнән күренгәнчә, ул Тукайның әкият герое исемен йөртә. Белмәгән кешеләр аны Андерсен әкияте героинясы исеме белән “Русалочка” дип тә йөртәләр. Иң борынгы фонтаннар булып 19 нчы гасырда ук төзелгән фонтаннар санала. Алар Кара күл бакчасында, Президент сарае каршында, опера театры артында урнашканнар. Иң биеге буып 50 м биеклеккә кадәр күтәрелүче Кабан күлендә Камал театры артындагы фонтан санала.

Гейзерллар турында ниләр беләсез? ***Җавап бирәләр.***

Ә гейзерларны исә табигый фонтаннар дип санарга мөмкин. Алар илебезнең Камчатка өлешендә урнашканнар. Гейзерлар аланы Россиянең 7 могҗизасы исемлегенә кергән.

Чишмәләрдә дә тоташкан савытлар законы ничек үтәлә? ***Җавап бирәләр.***

Рәсемнәрне игътибар белән карагыз әле? Сезгә танышлары юкмы? ***Җавап бирәләр.Тарих дәреслекләре буенча беләбез яки юк.***

Суткәргеч системалар да тоташкан савытлар законына буйсына. Ләкин монда су башнясына чистартылган суны насослар ярдәмендә тутырырга туры килә. Ә кулланучыга су үз басымы ярдәмендә бара.

Ә хәзер сууткәргечләрнең килеп чыгу тарихына күз салыйк. Алар тарихка акведуклар булып кереп калган. Борынгы инженерлар катлаулы техник мәсьәләләрне чишсәләр дә, гади генә физик законнарны белмәгәннәр. Алар озын трубалар ярдәмендә китерелгән су чыганаклар белән тигезләнеш хәленә килмәс дип курыкканнар һәм аны үз авырлыгы белән агарлык авышлыкта төзегәннәр. Аведуклар борынгы Рим белән бәйле булып күзалланса да, аларга кадәр йөз еллап алдан ук Якын Көнчыгыш илләрендә уйлап табылганнар. Вавилонлылар һәм гиптлылар катлаулы су тапшыру җайланмалары төзегәннәр. Безнең эрага кадәр 7 нче йөзъеллыкта ук австриялеләр башкалалары Ниневеяга су китерү өчен биеклеге 10 м, озынлыгы 300 м лы акведук төзиләр. Тулы озынлыгы исә 80 км га кадәр сузыла. Шул ук вакытларда майя шәһәрләрендә дә акведуклар төзелә. Борынгы Грециядә дә акведуклар төзелә. Ә Римга су китерү өчен 500 елда гомуми озынлыгы 350 км га җитккән 11 акведук төзелгән.аларның 47 км ы гына җир өстеннән үткән, калганнары исә җир астыннан үткән. Иң озын акведук безнең эраның II йөзъеллыгында Кафаген шәһәренә су китерү өчен төзелә һәм гомумми озынлыгы 141 км га җитә. Рим акведуклары бик катлаулы төзелешле була һәм Рим империясе таркалганнан соң 1000 ел үтсә дә искерми. Аның авышлыгы 1 км га 34 см гына була һәм вертикаль буенча 50 км да 17 м га гына түбәнәя.

Россиядә акведуклар зур шәһәрләрне су белән тәэмин итү өчен барлыкка килә. 1781-1804 нче елларда Мытище сууткәргечен төзү өчен Мәскәүдә беренче акведук төзелә. Мондый акведук Ташкентта да төзелгән.

**Укытучы:** Ә сез ничек уйлап караганыгыз бармы, кораблар электростанция корылмалары аша үтеп ничек югарына менәләр икән? (Балаларның фикерләре тыңлана) Моның өчен шлюзлардан файдаланалар. (флеш анимация ярдәмендә аңлатыла) Дөньяда гидроэлектростанцияләр күп булганлыктан, шлюзлар да күп төрле.

5. Рефлексия.

Максат: Белем үзләштерү дәрәҗәңне, бәя бирү; хатаңны күрә һәм төзәтә белү күнекмәләрен үстерү.

***Көйләгеч (регулятив):*** эшләгәннән соң үз хаталарыңны табу һәм төзәтү; эш алымнарына адекват ретроспектив бәяләү дәрәҗәсендә нәтиҗә ясау;

*Танып-белү: т*амга-символлы чаралар куллану ;

**Шәхси:** критерийлар нигезендә уңышлы уку эшчәнлегенә үзбәя кую.

**Укытучы:** Әйдәгез, үзебезнең нәрсә өйрәнгәнне тикшереп карыйк. Каршыгызда сары кәгазъгә басылган тестлар бар. Өстенә исем-фамилиягезне языгыз. Дөрес җавапларны түгәрәк эченә алыгыз. Сезгә 5 мин вакыт бирелә. ***Укучылар тест чишә.***

-Ә хәзер үз җавапларыгызны тактадагы җаваплар буенча тикшерик һәм критерийлар буенча билгеләр куеп карагыз. ***Үзбәя битенә билге куялар.***

**Укытучы:** бүгенге дәрестән үзегезгә нинди яңалык алдыгыз? Теманы аңлап җиттем дип саныйсызмы? Дәреснең кайсы өлеше ошамады? ***Фикерләрен әйтәләр.***

6. Өй эше. П.39, укырга,сорауларга җавап әзерләргә (121-124 бит; 2) Петергоф һәм Версаль фонтаннары турында материал табып, аларның аермасын белергә; 3) фонтан моделе ясап алып килергә.

## Э(Е) ХӘРЕФЕҺӘМ АВАЗЫ

*Шәмсетдинова Лилия Илдус кызы,*
*7 нче номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе",*
*Арча районы*

**Тема: Э(е) хәрефе һәм авазы**

**Максат:** 1) татар сүзләре һәм алынма сүзләрдә э(е) хәрефен дөрес язу, әлеге хәрефләр кергән сүзләрне дөрес әйтә, сөйләмдә дөрес аера белү күнекмәләре формалаштыру;

2) укучыларның чагыштыру, анализ ясый белү, кагыйдәләр формалаштыра һәм дәлилли белү күнекмәләрен үстерү, әдәби телдә дөрес һәм образлы итеп сөйләү телен үстерү, укучыларның сүзлек байлыгын арттыру.

3) татар халык авыз иҗаты аша укучыларга хезмәт тәрбиясе бирү.

**Көтелгән нәтиҗә**: [ә] авазын танып,сөйләмдә дөрес куллану, татар теленә генә хас үзенчәлеген аеру

**Предметара бәйләнеш**: татар теле, уку, әйләнә-тирә дөнья

**Шәхси нәтиҗә**:мөстәкыйльлек һәм җаваплылык, татар теленә карата ихтирамлы караш

**Дәрес тибы:** яңа материалны өйрәтү

**Материал**:дәреслек Ф.Ф.Харисов, Ч.М.Харисова, Е.А.Панова , 2 нче сыйныф, «Салават күпере» журналы, «Балалар фольклоры» китабы

**Җиһазлау**: презентация, карточкалар (тестлар)

**Дәрес барышы.**

**1. Оештыру. Эшчәнлеккә әзерлек**

Эмоциональ халәт тудыру.

**Укытучы**: - Кәефләрегез әйбәтме? Көнне яхшы сүз белән башласаң, бөтен көнең яхшы үтәр, - диләр. Әйдәгез әле, бер-беребезне яңа көн белән котлыйк

**2. Белемнәрне актуальләштерү**

Белем дәрәҗәсен тикшерү .

**Укытучы:**

1) "Йолдызлар кабызу " уены. Күк йөзе рәсеме ясалган плакат эленә.

-Тылсымчылар булырга телисезме? Әйдәгез, бергәләп күк йөзен йолдызлар белән бизик.

Укытучы укучыларга кәгазьдән ясалган йолдызлар өләшә. Аларга язылган сүзләрдә о, ы, ө,е хәрефләре төшереп калдырылып, алар урынына күп нокталар куелган. Укучылар йолдызлар артына язылган сүзләргә тиешле хәрефләр өстәп язалар, һәр яңа сүз әйтелгән саен яңа йолдыз "кабына".

**Борыч, болыт, йолдыз, сөлге, көзге, төтен, чөгендер, болын, колын, тозлы, йокы, төрле, көзге, соры, бөртек, дөрес**

Нәтиҗә: о һәм ө хәрефләре беренче иҗектә генә языла, калган иҗекләрдә ы, е хәрефләре языла.

**3. Уку мәсьәләсен кую. Проблемалы ситуацияне китереп чыгару.**

**1)Мотивлаштыру**

- Бүген мәктәпкә нинди уйлар белән килдегез?

- Урамда кешеләр очрадымы? Кая баралар икән алар?

- Бүлмәбез нинди?
- Кемнәр хезмәте, эше нәтиҗәсе икән бу?
-Ә сезнең төп эшегез нинди эш?
-Укып белем алмый торып, төрле һөнәргә өйрәнеп буламы?
- Эш турында, халкыбыз бик төгәл, дөрес сүзләр әйткән. Сезнең ишеткәнегез бармы?
Мәкальләрне уку, мәгънәсен ачыклау.
Эш кешене төзәтә, ялкаулык боза.
Эш беткәч, уйнарга ярый.
Эшләмәгән ашамый.
Эшләгән – ашый,
эшләмәгән – башын кашый.
-Дөрес , укучылар, эш эшләгән кеше беркайчан да начарлык эшләми, чөнки аның вакыты булмый.
**Уку мәсьәләсен кую.**
-Балалар, без яңа гына әйтеп үткән мәкальләр барысы да нинди авaздан башлана?
-Бүгенге дәресебезнең темасы нинди булыр?
-Дөрес, э(е) хәрефе һәм авазы.
**2) Артикуляцион гимнастика.**
Эс-эс-эс-эссе
Эш-эш-эш-бәлеш
Эл-эл-эл-элгеч
Эр-эр-эр-кишер
Че-че-че-чебен
Ке-ке-ке-керпе
Ре-ре-ре-эре
**4. Яңа материал өстендә эш.**
1. Матур язу күнегүе
Ээ Ээ
Эл эш эз ше ле зе
**Дәреслек өстендә эш.**
1. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү.
45нче күнегү – сүзләрне хор белән дөрес итеп уку.
- Бу сүзләрдә нинди сузык аваз ишетелә?
- Димәк, бу сүзләр барысы да нинди сүзләр?
- Дөрес. Сүз башында э авазы нинди хәреф белән белдерелгән?
- Башка иҗекләрдә э авазы нинди хәреф белән белдерелгән?
- Бер үк э авазы язуда ничә хәреф белән белдерелергә мөмкин икән?
**Дәреслектән кагыйдәне уку. 36 бит**
**Ял минуты .**Уен “Бас-утыр” – э авазы сүз башында ишетелсә, басарга тиеш.
***Эш, кеше, элмәк, иҗек, эзли, ирек, эт, эшли, итек, элә, өйдә, эссе, бәйрәм, элгеч.***
**5. Яңа белемнәрне куллану эшен оештыру.**
**Карточкалар:** Күнегүләр өстендә эш. Нокталар урынына э,е хәрефләренең тиешлесен куеп, шигырьне күчереп язарга.
- Биремне үтәр өчен нинди белемнәрне истә тотарга кирәк?(укучылар мөстәкыйль эшли, эш төгәлләнгәч тикшерелә )
Нәтиҗә. Э авазын язуда нинди хәрефләр белән белдердегез?
1. Рус һәм татар сүзләрен чагыштырып уку
***Эшче этаж***
***Энем электр***
***Эт эстафета***
***Эз эскимо***
- Кайсы баганадагы сүзләрдә э авазы киңрәк әйтелә? Ул сүзләр кайсы телдән алынган?

• Татар теленең үз сүзләрендә э авазы ничек әйтелә?
• Нинди нәтиҗә ясыйбыз? Э авазы ике телдә дә бармы?
• Әйе. Рус телендә ул ничек әйтелә?
• Ә татар телендә ул ничек әйтелә икән?

**Ял минуты**

Бер, ике- без бастык,
Чап-чап итеп кул чаптык.
Аякларны бер урында
Тып – тып –тып итеп бастык.
Утырдык, кабат бастык.
Бер утырдык, бер бастык.
Инде бераз хәл алдык,
Тыныч кына утырдык.

**6. Яңа белемнәрне мөстәкыйль куллану һәм тикшерү.**

1) тест (“Сузык авазлар” темасына)

1.Татар телендә ничә сузык аваз бар.
а) 9 б) 10

2.Татар телендә ничә калын сузык бар?
а) 5 б) 4

3.Татар алфавитының икенче хәрефе нинди?
а) б б) ә

4.Йолдыз сүзендә ничә сузык аваз бар?
а) 2 б) 3

5.Нечкә әйтелешле сүзне тап.
1. урам;
2. урдәк;
3. урак;
4. куркак.

6.Кайсы сүздә э хәрефе языла?
1. г...мбә;
2. п...си;
3. к...рпе;
4. …ремчек

7.Хаталы сүзне тап.
1. көрәк;
2. көзге;
3. сөлге;
4. өт.

-Дөреслеген слайд буенча тикшерәбез.

**Санамыш өйрәнү.**

Әке, пәке, кыек сәке,
Эремчек.
Син калып тор,
Энем, чык!

**“Тапкырлар” уены.**

Мин табышмаклар укыйм, сез җавабын табасыз һәм шул сүздә [э] авазының кайсы урында урнашуын (сүзнең башындамы, уртасындамы, ахырындамы икәнлеген) әйтерсез.

• Йомры йомшак сары йомгак
йөгереп йөри чирәмдә.(чеби)
• Кешенең дусты, йортның сакчысы.(эт)
• Яшел төймә күзләре,
Янып тора үзләре.

Төлке түгел – койрыклы,
Кеше түгел, мыеклы.(песи)
• Үзе бүрек кебек кенә,
Кигән туны энәле,
Бу ни була, кайда яши,
Берәрегез беләме?(керпе)
• Төбе алмалы, башы чалмалы.(бәрәңге)
• Сорыдыр төсе,
Үткендер теше,
Урманда йөри,
Бозаулар эзли.(бүре)
Җир астында җиз казык.(кишер)

**7. Рефлексия**

1.Кабатлау.

-Укучылар, дәресебезнең темасын искә төшерегез әле. Дәрестә нәрсәләр эшләдек?

-Бүгенге дәрестән үзегез өчен нинди яңалыклар алдыгыз? (Кагыйдәне кабатлау)

2.Үзбәя. (яшел,сары,кызыл карточкалары ярдәмендә эшләгәннәрне бәяләү; ни өчен теге яки бу төсне-билгене сайлауларын әйттерү.)

3.Билгеләр кую.

**8. Өйгә эш бирү.**

36 б. кагыйдә

1. “Әдәби уку” дәреслегеннән [э]авазы кергән 5 сүз табып алар белән җөмләләр язып килергә;
2. э хәрефе булган сүзләр белән кроссворд төзергә;
3. “Эш беткәч, уйнарга ярый” темасына кечкенә хикәя язарга

## ШӘРИП НӘСЕЛЕ

*Шәрипов Айбулат Илшат улы, 6 сыйныф*
*Фәнни җитәкче - Шәрипова Гөлия Мәгъсүм кызы,*
*Әгерҗе районы Ләбиб Айтуганов исемендәге*
*Девятерня төп гомумбелем бирү мәктәбе*

### Кереш

Эзләнү эшемне мин «Шәрип нәселе» темасына багышларга булдым. Конференциягә тәкъдим ителгән темаларның барысы да кызыклы, бүгенге көндә бик кирәкле, ләкин мин, туган авылымдагы иң зур нәселнең дәвамчысы буларак, үз нәсел шәҗәрәм белән горурлануымны яшерә алмадым һәм шуңа күрә әлеге теманы сайладым һәм, нәсел шәҗәрәсен өйрәнеп, туган ягымда аның нинди әһәмияткә ия булуын ачыклау максатын куйдым.

Эзләнү эшемне иң элек мин нәселемне барлаудан башладым. Нәсел шәҗәрәсен төзү минем өчен бик кызыклы булды. Бу эштә миңа әти-әнием, әбием һ.б. өлкән туганнарым, мәктәбемнең тарих укытучысы Илдус Нургаян улы Шайхутдинов ярдәм иттеләр.

Әйе, әйткәнемчә, Шәрип нәселе авылда иң зур нәсел булып санала.

### Тарихка күз салсак...

Нәсел шәҗәрәсен төзү туган ягым тарихын өйрәнү белән бергә үрелеп барды.

450 еллык тарихы булган авылыбызга нигез салучы Шымтылар минем ерак бабам Сәфәргали нәселенә нигез булып тора. 15ләп гаилә мари халкы яши торган Кады елгасы Көтмәскә койган төбәккә килеп урнашкан. Бу төбәк киек-җәнлеккә бай урманлы булган.

Сәфәргали бабабызның 6 баласы булган: Әбушәхмә, Габделлатыйп, Шаһиәхмәт, Гыйльметдин, Мөсифулла һәм Төхбәтуллалар. Шәрип нәселе Габделлатыйп бабайга барып тоташа. Габделлатыйп бабайның улы – Мөхәммәтзакир булган. Мөхәммәтзакир уллары - Шәрип, Бәйрәмхуҗа, Хәйдәр, Мөбәрәк, Әхмәтзарип. Аларның күп санлы нәсел дәвамчылары хәзер дә авылыбызда байтак. Ә Шәрип нәселен башлап җибәрүче Шәрипнең 7 баласы була: Нәҗип, Галимҗан, Фатыйма, Фәүзия, Фазылҗан, Әминә һәм Галимәләр. Шулар арасында Нәҗип бабай - минем Илдус бабамның әтисе. Кызганычка каршы, мин Илдус бабамны күрә алмадым. Мин туганчы, ул бу якты дөньядан китеп барган. Бу фәнни-эзләнү эшемне мин туганнарымның якты истәлегенә багышлыйм.

**Шәрип нәселе**

Бүгенге көндә Шәрипләр нәселе исемлегендә барысы 180 кеше исәпләнә: Нәҗип бабай ягыннан - 70, Галимҗан бабай ягыннан - 3, Фатыйма әби - 12, Фәүзия әби ягыннан - 5, Фазылҗан бабай тармагыннан - 50, Әминә әби ягыннан - 19, Галимә әби ягыннан - 21 кеше. Бу нәсел шәхесләре хәзерге вакытта бөтен Россия буенча таралганнар. Алар арасында төрле профиль студентларын, армия хезмәтендә Ватан сагында торучыларны, ерак юлга йөрүче шоферлар, тимер юл оешмаларында эшләүчеләр, югары квалификацияле укытучы һәм врачлар, телевидениедә алып баручы, бизнесменнар, кортчылар, тәрбияче, менеджерлар, архитекторлар, төзүчеләр, бухгалтер, электрик, сатучы, страхование һәм реклама агентлары һәм башка илебез халык хуҗалыгының башка тармакларында игелекле хезмәт итүчеләрне, хәтта АКШта, Германиядә юрист булып эшләүчеләрне күрергә мөмкин. Аларның күбесе авылда яшәмәсә дә, бүгенге көндә дә авылыбызда 21 Шәрип нәселе хуҗалыгы бар, аларда 55 кеше яши.

Бу эшемдә 55 кешенең дә эшчәнлеген тасвирлауны максат итеп куймадым, ә аеруча нәселебез тормышында үз эшләре белән танылган кешеләр эшчәнлеген яктыртырга булдым.

**Нәҗип бабай тармагы**

Сан ягыннан күпчелекне тәшкил итә (70 кеше), шулай ук аларның күбесе бүген дә авылда яши (36ы), шуларның 19ы мәктәптә эшли, укый яки тәрбияләнә.

Нәҗип бабай белән Бибиҗиһан әбинең Илгиз, Сәлимә, Илдус, Илфат, Илзур исемле 5 баласы була. Инде аларның бүген һәрберсенең балалары, оныклары күп. Барысы - 70 кеше. Алар да илебезнең төрле почмакларына таралганнар, ләкин күбесе авыл белән элемтәне өзмиләр.

Нәҗип бабай белән Бибиҗиһан әби озын гомер кичерәләр, балалары тәрбиясендә кадер-хөрмәттә яшиләр. Нәҗип бабай – 80 яшьне узып, Бибиҗиһан әби 100 яшен тутырып вафат була. Аларны соңгы юлга тәрбияләп озатып, шул нигезне саклаган уллары Илфат абый күптән түгел үзенең 70 еллык юбилеен уздырды. Илфат абыйның 3 баласы бар. Аның улы Фоат абый булдыклы хатыны Әнисә апа белән үз эшләрен башлап җибәрәләр: җәй көннәрендә иртәдән кичкә кадәр бал кортлары белән кайнашалар. Үзләре кебек игелекле 2 малай үстерәләр: Салават бүгенге көндә армия сафларында хезмәт итә. Нияз, 11нче сыйныфны уңышлы тәмамлап, бүгенге көндә Ижевск авыл хуҗалыгы академиясендә белем ала. Әнисә апа һәм Фоат абыйлар гаиләсе хәләл көч белән өр- яңа өй җиткереп чыктылар.

Илфат абыйның кызы Гөлфия апа, тормыш иптәше Илназ абый белән авылда төпләнеп, 3 бала үстерәләр, алар барысы да - мәктәптә уку алдынгылары. Илзур абыйның да 3 малае булып, бүгенге көндә олы уллары Илһам абый кортчылык белән шөгыльләнә, хатыны Эльфира апа мәктәптә укыта. Алар Элина һәм Энҗе исемле кызлар тәрбиялиләр.

Нәҗип бабайның иң өлкән улы Илдус - минем бабам - Клара әбием белән 3 бала тәрбияләп үстерәләр. Кызлары Роза белән өлкән уллары Ринат гаиләләре бүгенге көндә Ижевск каласында яшиләр һәм эшлиләр. Өченче бала – Илшат.

**Илшат онык**

Илшат онык минем әтием була. Гаиләдә төпчек малай булса да, ул иркә булып үсми. Кечкенә чагыннан ук Илдус бабамның төп ярдәмчесе була. Ир-егет бурычын үтәп, армия

хезмәтеннән кайткач, туган авылында төпләнеп кала, үзен төрле һөнәрләрдә сыный: Девятерня Мәдәният йорты җитәкчесе, мәктәптә лаборант, К. Маркс исемендәге колхозда тракторчы, урман хуҗалыгында мастер булып эшли.

Кызганычка каршы, авылыбыз бетә баручы авыллар исемлегендә: колхоз юк, яшьләр юк. Яшьләргә эш юк. Шулай диючеләргә әтием: "Эшлим дигән кешегә авыл җирендә эш бетәмени?!" – дип әйтергә ярата . Үзе дә тик тормый, һәрвакыт эштә, хәрәкәттә... Девятерня һәм Нарат авылларында ачылган шәхси кибете өчен авыл халкы рәхмәтле, ел әйләнәсендә кирәкле товар белән тәэмин итә. Пилорам сатып алып, авыл халкын гына түгел, тирә- як авылларны да агач материаллары белән тәэмин итә; утын, салам, печән сорап килүчеләрне дә кире бормый. Берничә ел рәттән басуда иген үстереп, авыл халкына да өлеш чыгара. Ул үзен чынлап та шушы җирнең хуҗасы итеп тоя, басуда күкрәп үскән игеннәрне күреп сөенә, чәчелмичә буш яткан җирләр өчен нык борчыла, болында чабылмыйча калган печән өчен авылдашларын ялкаулыкта битәрләп тә ала. "Җаны теләгән елан ите ашаган", ди халык, ирешелгәннәр белән генә чикләнмичә, Түбән Новгород шәһәреннән страус алып кайта, табигатьнең игелекле җан ияләре - бал кортлары үрчетә, абзар тутырып мал асрый.

Минем эти - әйткәнемчә, гаиләдә төпчек малай була, төп нигез хуҗасы. Ата - баба нигезен саклау ниндидер язылмаган законнар нигезендә бара безнең Шәрип нәселендә. Бүгенге көндә безнең гаиләдә 4 кеше яши: эти-әнием, әбием Клара һәм мин. 79 яшен тутыручы әбием гомер көзендәге бәхетле картлыгы өчен әтием Илшатка рәхмәтле. Үз вакытында оныклар тәрбияләүдә үзеннән зур өлеш керткән игелек иясе, йорт эшләрендә һич иренүне белмәгән тырыш хуҗабикә ул. Мәгънәле тормышы белән күпләргә үрнәк Клара әбием.

Минем 2 апам да авылда гаиләләре белән төпләнеп калдылар, һәр икесенең дә 3 әр балалары бар. Өченче апам Казан шәһәрендә белем ала. Нәсел дәвамчысы булып көттереп кенә, 4нче бала булып, мин, Айбулат, туганмын. "Әтиеңнең уң кулы," – бит син дияргә ярата әнием. Мәктәптә дә сынатмаска тырышам: алдынгы укучыларның берсе булып белем алам.

Кадерле әнием Гөлия дә шушы авылдан. Казан дәүләт университетын тәмамлап, укытучы булып эшкә кайткан яшь белгеч төп йортка килен булып төшә. Девятерня төп гомумбелем бирү мәктәбендә директор урынбасары, татар теле һәм әдәбияты укытучысы булып хезмәт куя. Аның җитезлеге, эштә уңганлыгы күпләрне сокландыра. Мәктәптән тыш вакытта гаиләдәге бихисап күп эшләрне башкарырга, кибет эшен җайга салырга ничек өлгерә ул?! Авылдагы концерт-кичәләрне бизәүче дә ул: җырчы, биюче, алып баручы да. Әтиемә булышырга да вакыт таба. "Эше барның ашы бар" - дияргә ярата әнием. Чыннан да, тормыш байлыгы, табын муллыгы олы хезмәттән тора. Шуңа да без, мин һәм минем 2 энекәшем, 2 сеңелкәшем (апамнарның малайлары һәм кызлары), гаиләбезнең төп ярдәмчеләре булырга тырышабыз. Хуҗалыкта бүгенге көндә күп санлы эре мөгезле терлек, сарыклар... Һәркайсына тәрбия, карау кирәк. Безнең арада эш тигез бүленгән. Кемдер тегермән тартканда, икенчебез ашлык ташып куя, кемдер кар көри, иртә-кич малларга ашарга бирү, су салу...

Эш беткәч, әниебезнең тәмле сыйларыннан авыз итүне көтеп кенә торабыз. Өстәл тирәли шау-гөр килеп сыйланып утыру - үзе бер бәйрәм. Тормыш ул бәйрәмнәрдән торырга тиеш тә! Әти-әни, әби-бабай янәшәсендә хезмәткә өйрәнеп үсү; мәгънәле яшәп, җәмгыятьнең кирәкле кешесе булу; тормыш кадерен , җиде буын бабаңны белү, аның эшен дәвам итү, нәсел саклау, җир сулышын тою, аны саклау - бурыч. Шул бурычны үти алу – үзе бер бәйрәм.

Мин туган ягымда якты эзен калдыручы гаиләм һәм нәселем белән горурланам.

### Укытучым Илдус Нургаян улының мәгънәле фикере

Бүгенге көндә Россия авыллары тирән кризис кичерә. Соңгы елларда авыл хуҗалыгында гаҗәеп үзгәрешләр булса да, бу үзгәрешләр авыл хуҗалыгы үсешенә уңай тәэсир итә алмады, рентабельле хужалыклар бармак белән генә санарлык, алары да күбрәк кара туфраклы уңай агроклимат шартлары булган көньяк районнарда. Дәүләт соңгы елларда

авыл халкының тормыш шартларын яхшырту буенча күп чаралар күрде: газлаштыру, юллар төзелү, элемтә чараларының яхшыруы һәм башка хезмәт күрсәтүләрнең сыйфаты яхшырды, ләкин... авыл картаюын дәвам итә, кризисны үтә алмый, моны статистика ачык раслый, күптән түгел булган авыл җыеннарында да бу турыда әйтелде. Авылны яшәртү, саклау турында бүген федераль биеклектән башлап, авылда көн дә Илшатның "Гөлли" магазины янына җыелып гәп коручы авыл картларына кадәр күп сөйлиләр, ләкин коры сүздән нинди файда! Тиешле чаралар соңарып кабул ителде шул! Авылны, авыл хезмәтен яратучы буын бүген юк дәрәҗәсендә. Минемчә, бүген авылга Илшатлар җитми... Эх авылда бүген Илшат – Гөлия гаиләсе кебек 10 лап гаилә булса иде. Шулай булганда, авылның демографиясе яхшырачак, урам тутырып көтү чыгачак, балалар бакчасы, мәктәпләр гөрләячәк...

Без һәрвакыт яхшыга өметләнәбез.

**Соңгы сүз**

Шәҗәрәмнән күренгәнчә, нәселемнең һәр кешесенең туган җиремдә үз эше, үзе салган эзе. Шуларны ачыклап, максатыма ирештем дип уйлыйм.

Авылыбыз, туган ягыбыз тарихында тирән эз калдырган һәм калдырачак нәселем белән чын-чынлап горурланам. Мин дә, үз чиратымда, нәсел горурлыгын саклауда сынатмам дип уйлыйм. Үзем белгән тарихны балаларыма җиткерергә, җиде буынны барлап, аларның якты истәлеген саклауда үземнән зур өлеш кертәчәкмен.

## КОШЛАР – КАНАТЛЫ ДУСЛАР

*Шәрифуллина Айгөл Флүс кызы,*
*Казан шәһәре Совет районының Советлар Союзы*
*герое С.Ә.Әхтәмов исемендәге 121 нче Лицее*

**Максат:**

**Белем бирү максаты:** Безнең якта яшәүче һәм чит җирләрдәге кошлар турында мәгълумат бирү.

**Фикер сәләтен үстерү максаты:** Кошларны танып белү, аларның яшәү рәвеше белән танышу.

**Тәрбияви максат:** Тирә-якка игътибарлы булу, ярдәмгә мохтаҗ кече дусларыбызны саклау, аларга яшәү шартлары тудыру өчен көрәш омтылышы тәрбияләү.

Җиһазлау: Проектор, кош рәсемнәре, Кызыл китап, карточкалар, Ала карга макеты, кош тавышы яздырган музыка.

| Дәрес этаплары | Этапның эчтәлеге |
|---|---|

| | |
|---|---|
**Изготовление гончарного круга**

Основным элементом, на котором все держится - является рама. При определении размеров рамы, исходил из размеров задней части бака стиральной машины, от мест его крепления. На задней части бака имеется узел с двумя подшипниками, где крутиться барабан. Этот узел нам и нужен. Конструкцию рамы я решил изготовить из металлической трубы квадратного сечения 25х25 мм, так как металл является долговечным, чем ДСП и фанера. Для этого мне понадобиться из инструментов болгарка и сварочный аппарат. Отрезаем необходимые отрезки трубы и свариваем между, собой используя струбцину. При сварке проверяем угольником правильность углов. Обрабатываем шлифовальной машиной сварочные швы. Для крепления электродвигателя свариваем на раму отрезок трубы прямоугольного сечения 25х40 мм. по чертежу. На эту трубу свариваем ушки с отверстиями для крепления самого электромотора. Свариваем для натяжения ремня ушко из угольника с отверстием на 12 мм. Теперь можно покрасить раму.

Необходимо ровно отрезать борта от задней части бака, увеличить крепежные отверстия, просверлив сверлом Ø 6 мм. Установить на раму и просверлить пять крепежных отверстий диаметром 6 мм на раме. Отрезаем излишки бака, которые выходят за раму. Теперь можно прикрепить болтами 6 мм бак к раме.

Вал барабана стиральной машины мы можем использовать только для определения размеров, при изготовлении вала гончарного круга, чертежи которого приведены. Вытачиваем на токарном станке вал. Шкив для вала используем от стиральной машины. Вытачиваем рабочее колесо диаметром 250 мм из металлического листа толщиной 10 мм. Рабочее колесо необходимо сделать съемным, для этого вытачиваем с внутренним диаметром 34 мм и с наружным диаметром 50 мм отрезок трубы длиной 65 мм. Нарезаем резьбу Ø 8 мм с боку для фиксации рабочего колеса на валу. Свариваем отрезок трубы на центр рабочего колеса. На этом металлическая часть изготовления гончарного круга окончена.

Обшивку корпуса выполнил из фанеры толщиной 8 мм. Закрутил к раме само резами. Покрыл грунт-эмалью.

**Изготовление регулятора оборотов электродвигателя**

Без регулятора оборотов невозможно выставить необходимые обороты для работы с глиной. Регулятор должен быть с плавным пуском электродвигателя и регулировкой оборотов от 0 до 300 об\мин. Под нагрузкой электродвигатель должен держать обороты. Быть достаточно надежным и безопасным. Разбирая схемы регуляторов оборотов для коллекторных электродвигателей, я натолкнулся на схему, где используется микросхема

TDA 1085. Данная схема используется многими гончарами при изготовлении самодельного гончарного круга.

Принципиальная схема регулятора оборотов с поддержанием мощности:

Из-за отсутствия деталей, пришлось все детали заказывать через интернет-магазин радиодеталей. Список необходимых деталей приведен в приложении. До прихода радиодеталей я занялся изготовлением печатной платы регулятора. Печатную плату делаем из стеклотекстолита одностороннего размерами 107x108 мм.

Зеркальный рисунок печатной платы:

Дорожки печатной платы сделаны обратной стороной для исполнения ее утюжной технологией. Рисунок печатной платы печатаем на глянцевой специальной бумаге на лазерном принтере. После этого распечатку ставим на стеклотекстолит и утюжим утюгом. Рисунки должны аккуратно перенестись на стеклотекстолит. Далее необходимо выполнить травление, для удаления ненужных дорожек на стеклотекстолите. Для этого я использовал лимонную кислоту и перекись водорода. Лимонная кислота продается в любом продуктовом магазине. Перекись водорода в таблетках можно приобрести за копейки в любой аптеке. Пакет лимонной кислоты 100 грамм надо растворить в воде и положить туда 5-6 таблеток перекиси водорода. Раствор для травления готов. Готовый раствор переливаем в ванночку и опускаем туда наш стеклотекстолит. Примерно через 30 минут раствор съедает ненужные участки фольги, а что под краской останется. После травления, печатную плату промываем под струей воды. Теперь можно просверлить монтажные отверстия Ø0.8-1 мм, для пайки проводов отверстия делаем Ø1.5 мм. Очищаем печатную плату от краски и производим лужение. Далее устанавливаем все детали согласно схеме. Семистор для охлаждения устанавливаем на радиаторе. Микросхему TDA 1085 устанавливаем на панельке, чтобы при необходимости можно было без пайки быстро заменить.

Припаиваем все провода.

Реверс для электродвигателя выполняем по схеме:

Для изменения полюсов при соединении электродвигателя используем тумблер.

Электодвигатель подсоединяем по схеме:

Вместо перемычки подключаем провода идущие от тумблера для реверса. В моей схеме используется тахогенератор. К нему идут два провода. Тахогенератор имеет обратную связь с регулятором оборотов.

При проверке работы данной схемы, у меня заработало все с первого раза. Теперь я установил данную собранную схему на раму гончарного круга. Провода скрепил между собой стяжкой.

**Изготовление чаши**

Для изготовления чаши я приобрел в магазине тазик за 100 рублей и переделал его под себя. Для этого в центре днища сделал отверстие Ø 55 мм. Взял отрезок канализационной трубы Ø60 мм длиной 60 мм и приклеил этот отрезок в центр днища, чтоб отверстие оставалось внутри трубы. Отрезок трубы необходим чтоб вода и масса глины не попадали при работе внутрь гончарного круга. Для крепления самой чаши использовал двухсторонний скотч.

**Себестоимость гончарного круга**

| № | Наименование | количество | цена за штуку | Итого (руб) |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Труба квадратного сечения 25x25 мм | 8 м | 74 | 592 |
| 2 | Фанера 8 мм | 1 шт | 450 | 450 |
| 3 | Труба прямоугольного сечения 25x40 мм | 0.2 м | 86 | 17.2 |
| 4 | Элементы стиральной машины автомат (шкив, ремень, электродвигатель, барабан, бак) | 1шт | 2000 | 2000 |
| 5 | Саморезы | 40 шт | 1 | 40 |
| 6 | Электроды 3 мм | 0.5 кг | 95 | 47.5 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 7 | Сверло Ø 6 мм | 1 шт | 32 | 32 |
| 8 | Сверло Ø 8 мм | 1 шт | 36 | 36 |
| 9 | Сверло Ø 10 мм | 1 шт | 40 | 40 |
| 10 | Сверло Ø 12 мм | 1 шт | 52 | 52 |
| 11 | Грунт-эмаль | 1 шт | 230 | 230 |
| 12 | Радиодетали | 1 шт | 2000 | 2000 |
| 13 | Стеклотекстолит | 1 шт | 180 | 180 |
| 14 | Сверло Ø 0.8 мм | 1 шт | 25 | 25 |
| 15 | Сверло Ø 1.2 мм | 1 шт | 28 | 28 |
| 16 | Перекись водорода | 1 пачка | 12 | 12 |
| 17 | Лимонная кислота | 2 пачки | 21 | 42 |
| 18 | Работа токаря (вал, рабочее колесо) | 1 шт | 850 | 850 |
| 19 | Припой | 1 шт | 46 | 46 |
| 20 | Провода | 5 м | 23 | 115 |
| 21 | Наконечники проводов | 20 шт | 1,5 | 30 |
| 22 | Термоусадочная трубка | 1 шт | 46 | 46 |
| 23 | Болт и гайка на 6 мм | 5 шт | 11 | 55 |
| 24 | Болт и гайка на 8 мм | 2 шт | 13 | 26 |
| 25 | Болт и гайка на 10 мм | 1 шт | 18 | 18 |
| 26 | Тазик для чаши | 1 шт | 100 | 100 |
| 27 | Клей Монолит | 1 шт | 15 | 15 |
| 28 | электроэнергия | 7.2 квт | 4.60 | 33.12 |
| Итого по всем пунктам | | | | 7157,82 |

По расчетам гончарный круг обошелся мне 7157,82 рублей. По сравнению с аналогичными по характеристике гончарными кругами я сэкономил в разы. промышленный гончарный круг стоит приблизительно 30000 рублей, то есть я сэкономил приблизительно 22842,18 рублей.

**Оценка гончарного круга.** Гончарный круг получился внешне довольно приличным. Регулятор оборотов поддерживает установленную мощность. Обороты регулируются в необходимых пределах для работы с глиной.

Достоинства:

1. Низкая себестоимость конструкции, по сравнению с промышленными
2. Простота конструкции
3. Детали для ремонта можно приобрести в ремонтной мастерской бытовой техники
4. Возможность повторить для получения прибыли
5. Возможность попробовать себя в качестве гончара

Недостатки:

1. Шумность работы
2. Рама обшита невлагостойким материалом.

При анализе проектной работы особенных недостатков не обнаружил.

Работа над данным проектом позволило мне изучить некотором уровне радиотехнику. Я попробовал себя в качестве электросварщика, токаря, что расширило мои возможности в сфере творческой деятельности. В целом, я доволен своей работой.

# ТЫЛСЫМЛЫ КАРТИНА

*Бәшәров Миндияр, 3 сыйныф укучысы,*
*Фәнни җитәкче: Бәшәрова Язилә Зиннур кызы*
*ТР Кукмара районы "Ядегәр урта гомуми белем бирү мәктәбе"*

Мин бүгенге эшемне "Тылсымлы картина" дип атадым. Картинаны кинусайга алымы кулланып ясадым. Кинусайга – безгә Япония иленнән килгән, үзенчәлекле сәнгать төре. Кинусайга техникасында кешеләр материя кисәкләреннән, энә кулланмыйча, бик матур картиналар ясыйлар. Бу техника бик авыр булмаса да, аны ясау өчен түземлек кирәк. Тәвәккәллегемне туплап, апама бүләк итү өчен, әлеге картинаны ясарга булдым.

Актуальлек. Кибетләрдә йөргән чагында мине матур-матур картиналар таң калдыра. Ә үзең бу матурлыкны ничек тудырып була? – дигән сорау туды миндә. Минем үз кулларым белән картиналар иҗат итәсем килде. Күп кенә материаллар белән танышканнан соң миңа шушы кинусайга алымы ошады. Мин бу алымны кулланып төрле картиналар ясарга булдым. Аның тарихы, килеп чыгышы, ясау этаплары, кирәкле материаллар турында белешмә тупладым.

I ӘЗЕРЛЕК ЭТАБЫ

ПРОБЛЕМАЛЫ СИТУАЦИЯ. Минем алдыма иҗади проектны сайлау проблемасы килеп басты. Бөтен вариантларны да караганнан соң, кинусайга алымын кулланып пар ябалак ясарга булдым. Карап торышка бу бик җиңел эш кебек тоела, ләкин бик күп вакытны сарыф итә. Шулай ук зәвык таләп итә. Мин барлык фантазиямне һәм иҗатымны күрсәтергә, бөтен кешене гаҗәпләндерергә булдым. Апама менә дигән бүләк булачак.

Иҗади проектымның максаты: кинусайга техникасын өйрәнү һәм бу техниканы кулланып, картина ясау.

Бурычларым:

- кинусайга техникасын кулланып картина ясауны һәм осталыкны ныгыту;
- эстетик зәвык һәм иҗадилыкны үстерү;
- эш сөючәнлек, пөхтәлек тәрбияләү

ТАРИХИ БЕЛЕШМӘ. Берничә гасыр элек Япониядә материя кисәкләре ярдәмендә картиналар ясау техникасы үсеш ала. Кинусайга техникасын Маэно Такаши уйлап таба. Башта бу сәнгать бик актуаль була, соңыннан аның турында оныталар. 80 нче елларда ул кабат яңара һәм безнең илгә дә үтеп керә. Японнар бу техника белән эшләү өчен ефәк тукыма кулланганнар. Хәзерге көндә картиналарны ефәктән генә түгел, башка тукымалардан да ясыйлар.

Традицион Кинусайганы ничек ясаганнар соң? Иң беренче эш итеп рәссам булачак картинаның эскизын кәгазьгә ясаган. Аннан соң әзер булган эскиз тактага төшерелгән. Тактада 2 мм тирәнлектәге батынкылыклар кискәннәр. Ефәк тукымаларны кисәкләргә бүлгәннәр һәм аларны киселгән канаучыкларга куйганнар. Кинусайга ярдәмендә пейзажлар сурәтләнгән. Кешене сурәтләү хәтта профессионалларга да авыр бирелгән.

Кинусайга техникасы бөтен бүген бөтен дөньяга таралган. Хәзер такта кисәкләре урынына пенопласт кулланалар. Ефәк тукыманы гади материя алмаштыра.

Кинусайга техникасын картиналар ясау өчен генә түгел, ә хәзер аны шкатулкалар бизәү өчен дә кулланалар.

ИҢ ЯХШЫ ИДЕЯНЫ САЙЛАУ. Мин хыялланырга бик яратам. Шулай ук кошлар дөньясы да миңа таныш. Шуңа күрә мин пар ябалакларны сайлап алдым. Аны үземчә үзгәртеп, баетып эшләргә булдым. Ясау буенча минем яшь үзенчәлегемә дә туры килә.

ТЕХНОЛОГИК КАРТА

Картинаны ясау технологик карта ярдәмендә ясала. Эш тәртибе түбәндәгечә башкарыла (кушымта 2): Пар ябалакларның шаблонын ясау, шаблон ярдәмендә эскизны нигез пенопластка төшерү, канцеляр пычагы белән пенапластка төшергән эзләр буенча кисеп канаучыклар ясау, тукымаларны эскиздагыдан зуррак итеп кисү, пилка ярдәмендә

тукымаларны канаучыкларга кертәбез. Канат өлешеннән башлыйбыз. Башка өлешләр дә шул тәртиптә эшләнә. Ахырдан рамка эшләнә. Аннан соң күзләре һәм фонда йолдызлар ябыштырыла.

ЙОМГАКЛАУ ЭТАБЫ

ЭКОНОМИК ИСӘПЛӘҮ. Картинаны ясау өчен чыгым бик күп булмады. Клей, кацеляр пычагы, сатып алдым. Калган әйберләр үземдә бар иде.

Үземнең хезмәтемне исәпләмәгәндә, мин түбәндәгечә экономик исәпләү ясадым.

Картинаны ясау, үземнең хезмәтемне исәпләмәгәндә, 100 сумга төшә.

ЭКОЛОГИК НИГЕЗЛӘҮ. Кинусайга ысулы белән ясалган картиналар экологик яктан чиста. Бүгенге көндә үз кулың белән ясалган әйберләр зур бәягә ия.

Экологик яктан бу картиналарның сәламәтлек өчен бернинди дә зыяны юк, киресенчә, ул кәефне күтәрә, бүлмәгә матурлык өсти.

Кинусайга ысулы белән эшләгәндә санитар – гигиеник таләпләрне төгәл үтәргә кирәк. Куркынычсызлык кагыйдәләрен дә тиешенчә белү һәм үтәү мәҗбүри. Шулай ук, эшкә керешкәнче, эш урынын әзерләргә кирәк.

ЭШКӘ ҮЗАНАЛИЗ. Ясалган картинам иҗади, вакытны һәм акча ягын күп сарыф итмичә матур килеп чыкты. Бүлмәнең һәр стенасында мондый картинаны күрү барлык кешеләрне дә сөендерер.

Мин бу проектның темасын алып дөрес эшләдем дигән нәтиҗә ясадым. Әгәр дә без үз алдыбызга максат итеп матур һәм оригиналь әйберләр ясауны куябыз икән, шул вакытта гына үз кулларыбыз белән әйбер ясый алачакбыз. Әгәр миннән “Мондый матур, кызыклы картинаны кайдан сатып алып була” дип сорасалар, мин горурланып әйтә алам: Мондый картинаны сатып алып булмый! Аны бары тик теләк һәм тырышлык булганда гына эшләп була. Киләчәктә бу эшемне дәвам итәчәкмен, яңадан-яңа картиналар тудырырмын. Иптәшләремне, туганнарымны яңа картиналар белән сөендерермен.

РЕКЛАМА. Әгәр сезнең йортыгызны шушындый үзенчәлекле, кызыклы, бернинди кибетләрдә дә сатылмый торган картиналар белән бизисегез килә икән, рәхим итегез! Бары тик ООО “М.Б.М” фирмасы картиналарга заказлар кабул итә. Телефон: 35-5-67. Адрес: Кукмара муниципаль районы, Ядегәр авылы, Мәктәп урамы, 3нче йорт.

ЙОМГАКЛАУ. Бу эшемне башкарганда мин иҗади проект эшчәнлеге турындагы белемнәремне тагын да баеттым. Күләмле эшне башкарып чыгуда үземне, үземнең көчемне сынадым. Кадерле апама менә дигән бүләк әзерләдем.

*КУЛЛАНЫЛГАН ӘДӘБИЯТ*

1. Выгонов В.В. «Технология лоскутного шитья». Издательство «Экзамен» 2014г.

2. Дамские рукоделия. Пэчворк - искусство вдохновения - http://www.ma-dam.ru/index.php?menu_id=373&menu_parent_id=329\

3. Лоскутное шитье. От истоков до современности // - http://www.museum.ru/N20175

# ОСТА КУЛДА ҺӨНӘР БАР

*Бәшәрова Ясминә, 1 нче сыйныф укучысы,*
*Фәнни җитәкче: Гилмуллина Рамилә Нургаян кызы*
*Т РКукмара муниципаль районы«Ядегәр авылы урта гомуми белем бирү мәктәбе»*

Миңа күп вакыт эссе җәй, ромашкалар белән матур клумбалар, пионнар, лилия, роза һәм башка күп кенә чәчәкләр искә төшә. Чәчәкләрне бик яратам! Алар кешеләргә бик күп сөенеч, яхшы кәеф бүләк итәләр, фантазияне кузгаталар, өйне ямьләндереп һәм бизәп җибәрәләр. Безнең шундый матурлыкны кулда тотар өчен күп кенә акчаларны сарыф итәбез. Кешеләр кулында күпләгән сортлы чәчәкләр була, алар төсләре , формалары белән дә аерылып торалар. Ләкин онытырга ярамый, чөнки өзгән чәчәк озак тормый, үзенең матурлыгын тиз арада югалта.

Үземнең иҗади эшемне дә “Оста кулда һөнәр бар” дип атадым. Чөнки иҗади эшем күп кешенең кулыннан килгән фоамираннан чәчәк ясау белән башкарылса да, минем яшькә бу эш гади түгел иде. Тәвәккәллегемне туплап, фоамираннан көнбагыш чәчәге ясарга булдым.

Теманың актуальлеге. Интернетта утырган вакытта, мине матур чәчәкләр таң калдырды. Тикмәгә генә аларны матурлыкның эталоны дип әйтмәгәннәр. Шул матурлыкка сокланган вакытта фоамираннан чәчәк ясау идеясы килде дә инде. Матур да, экономияле, һәрвакытта актуаль дә. Мин үземнең бүлмәмне фоамираннан эшләнгән чәчәкләр белән бизәргә булдым.Чөнки үз кулың белән эшләнгән әйберләр йортка җылылык һәм зәвыкъ алып килә. Шуннан соң эзләнә башладым, аның тарихы, килеп чыгышы, ясау этапларын, нәрсәләр кирәк.

ТӨП ӨЛЕШ. ТЕОРЕТИК ЭТАБЫ. Минем алдыма иҗади проектны сайлау проблемасы килеп басты. Бөтен вариантларны да караганнан соң, фоамираннан чәчәк ясарга булдым. Карап торышка бу бик җиңел эш кебек тоела, ләкин бик күп вакытны сарыф итә. Шулай ук зәвык таләп итә. Мин барлык фантазиямне һәм иҗатымны күрсәтергә, бөтен кешене гаҗәпләндерергә булдым.

Иҗади проектның максаты итеп фоамираннан чәчәк ясау өлкәсендә үземнең мөмкинлекләрне камилләштерүне алдым.

Бурычлары:

- фоамираннан чәчәк ясауны һәм осталыкны ныгыту;
- эстетик зәвык һәм иҗадилыкны үстерү;
- эш сөючәнлек, пөхтәлек тәрбияләү.

БАШЛАНГЫЧ ИДЕЯЛАР. Бу эшемне ясый башлаганчы, интернеттан чәчәкнең берничә төрлесен эзләп таптым һәм үземә ошаганын сайлап алдым.

ИҢ ЯХШЫ ИДЕЯНЫ САЙЛАУ. Мин хыялланырга бик яратам. Табигатьтә йөрү, төрле яңа әйберләр белән танышу минем күңелемә бик якын. Бигрәк тә чәчәкләрне яратам. Шуның өчен көнбагыш чәчәген ошаттым.

ТАРИХИ БЕЛЕШМӘ. оамиран- сыгылмалы (пластичная) замш яки Foamlran – йомшак зур табак битләрдәге кул эшләрендә киң кулланыла торган материал. Аны төрле исемнәрдә күрергә һәм ишетергә мөмкин: "Фом Эва", "Фоамиран", "Фоам", "Foam", хәтта "Ревелюр".

Шома һәм юка фоамиранның дәүләте булып Иран тора, шуннан аны Россиягә алып кайталар. Хәзерге вакытта сыгылмалы замшны төрле илләрдә ясыйлар, иң киң кулланылышта иран һәм кытай фоамираны. Структурасы буенча, фом губкага ошаган. Эластиклыгы һәм ныклыгы буенча, аның составында этилен һәм винилацетат бар. Фоамиранга кирәкле форманы бирү өчен мастерга фомны аз гына тарту яки кул белән бөтерү кирәк.

Сатуда фом рулоннарда кулланыла. Аны кул эшләре кибетләреннән, салоннардан, шулай ук интернет челтәрләреннән дә сатып алырга була.

ДИЗАЙН-СПЕЦИФИКАЦИЯ

Көнбагыш чәчәген ясый башлаганчы әллә никадәр сорау туа:

1. Ничек итеп ясарга
   а) фоамиран әзерләү; б) шаблонны әзерләү; в) ясау технологиясе;
2. Эш кораллары, җайланмалар.
3. Кайда урнаштырырга, күләме, формасы.

Фоамиран чәчәген ясау технологик карта ярдәмендә башкарыла. Эш тәртибе түбәндәгечә бара (кушымта 2): чәчәк шаблоннарын ясау, шаблон ярдәмендә чәчәк таҗларын һәм яфракларны фоамиранга төшерү, таҗларны кисү, таҗларны үтүк ярдәмендә эшкәртү, киңлеге 3 см, 2 см булган полоскалар кисү һәм бахрама ясау, бахраманы түгәрәкләп клей ярдәмендә ябыштыру, бахрама өстенә таҗларны клей белән беркетү, яфракларны беркетү, әзер детальләрне чыбыкка тоташтыру, тейп лента белән бизәү, рамканы материал белән тышлау, чәчәкләрне рамкага урнаштыру, декоратив ваза һәм бөҗәкләр белән бизәү.

Картинаны ясар өчен чыгым бик күп булмады. Клей, бөҗәкләр, рамка сатып алдым. Фоамиран, тукыма үземдә бар иде.

Үземнең хезмәтемне исәпләмәгәндә, мин түбәндәгечә экономик исәпләү ясадым.

Бу чәчәкне ясау барлыгы, үземнең хезмәтемне исәпләмәгәндә, 250 сумга төшә.

Э К О Л О Г И К  Н И Г Е З Л Ә Ү. Фоамираннан әйберләр ясау хәзерге заман кулланылышында, чөнки экологик яктан чиста һәм үз кулың белән ясалган әйберләр хәзерге көндә зур бәягә ия.

Экологик яктан фоамираннан ябыштырып ясалган әйберләрнең сәламәтлек өчен бернинди дә зыяны юк, киресенчә, ул кәефне күтәрә, күңелне тынычландыра, бүлмәгә матурлык өсти.

Фоамиран белән эшләгән вакытта санитар – гигиеник таләпләрне төгәл үтәргә кирәк. Куркынычсызлык кагыйдәләрен дә тиешенчә белү һәм үтәү мәҗбүри. Шулай ук, эшкә керешкәнче, эш урынын әзерләргә кирәк.

Э Ш К Ә  Ү З А Н А Л И З. Ясалган чәчәк композициясе иҗади, вакытны һәм акча ягын күп сарыф итмичә матур килеп чыкты. Бүлмәнең һәр почмагында мондый композицияне күрү барлык кешеләрне дә сөендерер.

Мин бу проектның темасын алып дөрес эшләдем дигән нәтиҗә ясадым. Әгәр дә без үз алдыбызга максат итеп матур һәм оригиналь әйберләр ясауны куябыз икән, шул вакытта гына үз кулларыбыз белән әйбер ясый алачакбыз. Әгәр миннән "Мондый матурлыкны кайдан сатып алып була" дип сорасалар, мин горурланып әйтә алам: Мондый әйберне сатып алып булмый! Аны бары тик теләк һәм тырышлык булганда гына эшләп була. Киләчәктә бу эшемне дәвам итәчәкмен, яңадан-яңа идеялар тудырырмын. Иптәшләремне, дусларымны яңа чәчәкләр белән сөендерермен.

*КУЛЛАНЫЛГАН ӘДӘБИЯТ*


1. Алена Семенова "Цветы из фоамирана"
2. Ольга Воробьева «Цветы и композиции из фоамирана»
3. http://heaclub.ru/cvety-iz-foamirana-master-klass-kak-sdelat-cvety
4. http://zhenomaniya.ru/articles/show/mk-tsveti-iz-foamirana

# ПУТЕШЕСТВИЕ ПО РУССКИМ НАРОДНЫМ СКАЗКАМ

*Газизуллин Нияз, ученик 3а класса*
*Научный руководитель: Саматова Зульфия Наиловна,*
*МБОУ «Гимназия №1 имени Ч.Т.Айт- матова п.г.т.*
*Кукморского муниципального районаРТ»*

Лэпбук – сравнительно новое средство обучения. Впервые создавать лэпбуки начали американцы. Лэпбук - это книжка-раскладушка с кармашками, дверками, окошками, вкладками и подвижными деталями, в которую помещены материалы на одну тему.

Конечно, американцы не изобрели велосипед – похожие развивающие книжки или книжки-игрушки были всегда, но все-таки благодаря им лэпбукинг выделился в отдельный жанр. И, как и другие полезные новшества с запада, этот жанр удачно подхвачен и развивается в России.

Лэпбук «Путешествие по русским народным сказкам» представляет собой раскладную книжку формата А 4. На страницах книжки имеются различные кармашки, в которых собрана информация по теме. Он включает в себя различные творческие задания, привлекает своей необычной формой, радужным цветом, разнообразием игр и заданий. С помощью этого лэпбука материал усваивается без всяких усилий.

Цель:

Лэпбук создан с целью расширения знаний о народных сказках, для развития всех компонентов устной речи, практического овладения нормами речи на примерах русских народных сказок.

Задачи:

1.С помощью сказок развивать мышление, речь, воображение, память, наблюдательность, воображение, мелкую моторику, смекалку.

2.Проявить интерес к художественной литературе.

3.Обогащать словарный запас.

4.Развивать желание выполнять совместные игровые задания одноклассниками, братьями и сёстрами, интересно и с пользой проводить время.

5.Научиться различать народные сказки от литературных.

Актуальность:

Почему мы выбрали тему «Путешествие по русским народным сказкам»?

1.Сказки- прекрасное творение искусства. Наша память неразлучна с ними. Русская сказка создала замысловатый мир. Все в нем необыкновенно: топор сам рубит лес, печка разговаривает, яблоня укрывает своими ветвями детей, бегущих от посланных Ягой гусей-лебедей…

2.Народные сказки привлекают детей и взрослых своими необычными историям, чудесами и превращениями.

3.Благодаря им мы понимаем, что жизненный путь труден. Что каждое испытание помогает стать сильнее. Сказка намекает, что сделать правильный выбор помогает любящее сердце.

4.Она учит человека жить, вселяя в него веру в добро и справедливость, вызывая у нас сочувствие к обиженным героям. В результате сопереживания появляются не только новые знания, но и самое главное - эмоциональное отношение к окружающему: к людям, явлениям.

5. Из сказок мы узнаём много нового: представления о времени и пространстве, о связи человека с природой, предметным миром.

6.Долгие века народные сказки играли в жизни человека такую же роль, как в наше время книги, журналы, газеты, телевидение, радио, интернет и другие распространенные источники информации. Сказки – это настоящая бытовая энциклопедия прошлого, настоящего, и даже, возможно, будущего.

7.Народные сказки-это основа литературных сказок. Всем же известно: у великих поэтов А.С. Пушкина и Г.Тукая персонажи и сюжеты сказок были взяты из устного народного творчества.

8.Народную сказку справедливо можно считать одним из важных воспитательных средств. Сказки помогают развивать воображение, творческое мышление, речь подводить нас к логическим суждениям. Они служат могучим действенным средством умственного, нравственного и эстетического воспитания.

9.Сказка учит нас познавать себя самого и мир вокруг нас.

Практическая значимость:

Лэпбук «Путешествие по русским народным сказкам» предназначено для детей старшего дошкольного возраста и учащимся начальных классов. Он хороший помощник учителям русского языка и литературы, начальных классов, воспитателям детских садов и группы продленного дня. Данную книжку можно использовать на уроках литературного чтения, при проведении классных часов, викторин. Можно использовать как настольная игра с членами семьи, одноклассниками, друзьями. Можно при помощи этого лэпбука занимать гостей. Лэпбук отличный подарок на дни рождения или к другим знаменитым датам, ведь он сделан с любовью и старанием.

План работы:

1.Выбор темы.

2.Поиск и сбор информации.

3.Задумка конструкции лэпбука.

4.Приготовление материалов.

5.Создание лэпбука.

6.Красочное оформление.

7.Раскладка материалов по кармашкам.

8.Заявка на конкурс лэпбуков по теме «Устное народное творчество, традиции и обычаи»

9.Презентация своего лэпбука «Путешествие по русским народным сказкам»

10.Приятное и полезное времяпровождение с лэпбуком.

Содержание:

1.Википедия. Русские народные сказки.

2.Список русских народных сказок.

3. Тексты русских народных сказок ( нераспространенные).

4.Сюжетные картинки по сказкам.

5.Русские народные сказки в электронном носителе.

6.Дидактические игры.

7.Подвижные игры.

8.Кроссворды.

9.Ребусы.

10.Сказочные физкультминутки.

11.Шарады.

12.Викторины.

13. Книжки-гармошки «Загадки».

14.Раскраски по сюжетам сказок.

15.Пазлы, разрезные картинки.

16.Маски для инсценировок.

17.Тесты.

18.Театр на палочках.

19. Репродукция картин известных художников по русским народным сказкам.

20.Презентации к русским народным сказкам на электронном носителе.

21. Кармашек « Я-художник».

22.Кармашек «Творческая мастерская» ( наши сочинения, выступления, стихи, отзывы о народных сказках…).

23.Конкурсы.

24.Карточки с заданиями.

25.Инсценировки.

26.Головоломки.

Перспективный план:

Поиск и сбор информации, создание лэпбука мне очень понравились. Надеюсь, что он понравится моим друзьям, я хочу им сделать сюрприз. В дальнейшем хочу более подробно изучить русские народные сказки, мифические образы и дополнять новыми материалами кармашки своего лэпбука.

Заключение:

Своё выступление хочу закончить словами великого русского педагога В.А.Сухомлинского: « Дети должны жить в мире красоты, игры, сказки, музыки, рисунка, фантазии и творчества». В этом мне и моим друзьям поможет мой лэпбук «Путешествие по русским народным сказкам». И надеюсь таких лэпбуков у меня будет много.

Пожелание:

Мой добрый друг!
Бери с собой в дорогу
Своих любимых сказочных друзей.
В заветный час они тебе помогут
Найти мечту и сделать жизнь светлей.

*Список литературы*

1. Русские народные сказки. М.: Омега, 1997.
2. Русские народные сказки. М.: Педагогика, 1994.
3. Русские сказки. М.: Авлад, 1992.
4. Сказки из лукошка. М.: Кавалер, 1994.
5. Сказки о Бабе Яге. М.: Станок ПРЕСС, 2002.
6. Сказки о богатырях. М.: Станок ПРЕСС, 2003.
7. Сказки о животных. М.: Станок ПРЕСС, 2002.
8. Шаров А. Волшебники приходят к людям. М.: Детская литература, 1985.
9. Энциклопедический словарь юного литературоведа. М., 1987.
10. Энциклопедия для детей. М.: Аванта+, 1998. Т.9: Русская литература.
11. Сайты учителей начальных классов, русского языка и литературы.
12. Литвинова М.Ф. Русские народные подвижные игры. М: Детская литература, 1995

## ЯКУБ БАБАЙ ЧИШМӘСЕ

*Бикбаева Алинә, 3 сыйныф укучысы.*
*Фәнни җитәкче: Арсланова Гөлсем Фаил кызы,*
*ТР,Саба районы“Байкиев К.С. исемендәге Икшермә кадет мәктәп – интернаты”дәүләт бюджет гомуми белем учреждениесе*

Җир йөзендә мәңгелек кыйммәтләр бар. Шундый кыйммәтләрнең берсе, һичшиксез, чишмәләребездер. Кеше гомер буе аларның тылсым көченә табынган, алардан көч алган. Су – музыка бит ул. Нинди генә тавышларны яшереп сакламый су үзендә. Чулпы чылтыравы да, кыңгырау чыңы да бар ул тавышлар арасында. Урманда, басуларда, болыннарда йөреп

сусагач, чылтырап аккан чишмә буенча килеп чыксаң, суның чисталыгына карап, аның җирдән бәреп чыгуын күреп, сүзсез калып торасың. Ә аның суын татып карагач, нинди салкын, нинди тәмле икәнен тоясың.

Һәркем үзе яшәгән урынның тарихы белән кызыксынадыр. Берсеннән- берсе серле, кызыклы исемнәр каян килеп чыккан соң, кемнәр кушкан аларны? Шушы сорауларга җавап эзләп, мин дә үзебезнең чишмәләрне барларга һәм Татар Икшермәсендә урнашкан "Якуб бабай" чишмәсен өйрәнергә булдым. Иң беренче эш итеп мин авылыбызның өлкән яшьтәге ак әбисе –Камилә әбидән чишмәнең килеп чыгу тарихын сораштым, аннан соң укытучыбыз белән берлектә проект эше башкардым. Бу эшләрнең нәтиҗәләрен сезгә җиткерергә булдым. Безнең бурыч: үз авылыңның чишмәләренең тарихын белү; "Якуб бабай" чишмәсенең килеп чыгышын белү; алга таба авыл тарихын саклап калуда нинди эшләр башкара алачагыбызны планлаштыру.

Максат:

Чишмәләр турындагы белемнәрне киңәйтү.

Чишмәләр тарихы,аларның урнашу урыны белән таныштыру

Матурлыкны күрә белергә,аның белән сокланырга күнектерү.

Чишмә исемнәрен истә калдырырга ярдәм итү.

Чишмәләрне саклап калырга дигән төшенчә кертү.

ЧИШМӘЛӘР ТУРЫНДА ГОМУМИ МӘГЪЛҮМАТ.

Ата-бабаларыбыз суның кадерен белгәннәр,зурларын һәм кечерәкләрен дә аерым атама белән йөрткәннәр.Җөмһүриятебездә Идел,Чулман,Нократ кебек мәһабәт елгалардан башлап һәр вак чишмәнең исеме бар.Ә нәрсә соң ул чишмә?

Җир астыннан агып, бәреп чыга торган су чишмә дип атала . Чишмәләр-кечкенә генә булсалар да, табигатькә җан кертүчеләр, елга, күл, инеш, диңгез һәм океаннарга тормыш өрүче. Халык әйтсә, чынлап та, хак әйтә. Чишмәләргә карата кулланылган "Башы – тауда, аягы – диңгездә" дигән табышмак аларның җитез, йөгерек, эшчән, халыкка намус белән хезмәт итүчән табигатьләрен бик дөрес сурәтли.Идел, Чулман (Кама) кебек мәһабәт елгалар да кайчандыр кечкенә генә , бала да атлап чыга алырлык бәләкәй чишмәләрдән башланып киткәннәр. Исәбе-хисабы булмаган чишмә, инеш, елга-су кушылдыклары белән туклана-туклана, алар тора-бара зур елгаларга әверелгәннәр.

Еллар үткән саен, кешеләрнең тормышы яхшыра барган. Хәзер байлык, мал – мөлкәт туплау йогышлы чиргә әверелә бара. Чишмәләр онытыла. Алар янындагы агачлар киселә, сындырыла, тирәсен мал – туар таптый. Ә шулай да чишмәләр исән кала. Чал тарих исән! Бүген дә алар безне саф сулары белән куандыра. Ел саен чишмә буенда татар халкының милли бәйрәме Сабантуй уздырыла.

Чишмәләр. Гореф – гадәтләр. Алар бер – берсен тулыландырып, матурлап торалар. Яшь киленгә су юлы күрсәтү – татар халкының бик борынгыдан килгән йолаларыннан берсе. Килен башка авылдан төшсә дә, үз авылыннан булса да, беренче мәртәбә суга үзе генә бармый. Йола буенча аны, кыз җиңгәсе яки күрше кызлары, яисә кияүнең сеңлесе озата бара. Чишмәне һәм су юлын күрсәтүчеләргә бирү өчен, яшь килен бүләкне алдан ук әзерләп куя. Су юлын күрсәтүчеләр килен бүләген – чиккән яулыкны, тастымал, алъяпкычны бик теләп алалар. Алар, су алып кайтканда, яшь киленне сыныйлар. Су чиләктән түгелмичә кайтырга тиеш. Су түгелмәсә - килен сабыр холыклы, түземле булыр; түгелсә - чайкалса, бераз кызу холыклырак булмагае, дип юрыйлар. Яшь килен алып кайткан суны "ширбәт" дип туй өстәленә дә куялар. "Су нинди саф, яңа өйләнешүчеләр тормышы шул су кебек матур, чиста, озын гомерле булсын", дигән теләкләр теләп эчәләр кунаклар яшь килен алып кайткан суны.

Чишмәләрнең әһәмияте бик зур. Халык чишмәләрне бик зурлый. Бу тикмәгә генә түгел. Без көн саен чәй кайната, аш пешерә, юына һәм коена торган шушы гап – гади суның искиткеч гаҗәеп яклары, тылсымлы сыйфатлары бар. Күз алдына китерүе дә кыен булган дәрәҗәдә озын гомерле ул су! Без иртә торуга битне юа яисә ансат кына эчеп җибәрә торган шушы төссез сыекчада 60 тан артык химик элемент бар диләр. Сусыз яшәү мөмкин түгел. Кеше ашамыйча атналар буе тора ала. Әмма сусыз берничә көнгә дә түзә алмый. Әгәр кеше

тәнендәге суның уннан бер өлеше генә кимесә дә, аның хәле начарлана, диләр галимнәр. Менә бит суда нинди тылсымлы көч бар. Чишмәләргә кешеләр борынгы заманнардан ук табынып яшәгәннәр.Чишмә суларын эчеп дәвалананнар. Чишмәләр сафлыкка,чисталыкка өндәгән.Чишмәләр янында кешеләр сафланып , чистарып киткәндәй була. Судагы могҗиза берни белән дә чагыштырыла алмый. Күз тигән һәм гомумән авырган кешеләрне таң суы алып коендыра торган гадәт тә суның илаһи көче турында сөйли. Таң суы белән коендыру йоласы төрле урыннарда төрлечә. Ләкин барлык җирләрдә дә ул кояш чыкканчы алына. Кирәкле догаларны укыгач, шунда ук яисә бер-ике төн кундыргач, авыруны шул су белән коендыралар. Авыру шушы гамәлдән соң, һичшиксез, сихәт ала.

Безнең якларда эчә торган су запасы күп. Шул сәбәпле, әле хәзергә су кытлыгы көтелми. Кайбер илләрдә суны, самолет белән ташып, җан башына карап бүләләр. Дөньяның кайбер шәһәрләрендә гап – гади суны стаканлап саталар.Бу хәлләр безне дә сагайтырга, табигатьнең бу кадерле бүләгенә игътибарлы булырга кирәклекне искәртергә тиеш. Чөнки чишмәләре кибеп сусыз калган авыллар бездә дә юк түгел.Чишмәләр ни сәбәпле корый? Чишмә чыга торган урман яки агачлык киселеп бетә дә чишмә тирәсе, киемен салдырып алган кеше шикелле, ялангачланып кала. Бу урынны терлек – туар таптый, ул чүпләнә, пычрана. Шуннан соң чишмәнең корымый хәле калмый. Чишмә артыннан аның суы белән туклана торган инеш тә кибә. Ул арада, дым булмагач, чишмә һәм инеш буенда үскән куаклар, үләннәр, болыннар да корый. Бу тирәгә кош – корт та оя ясамый. Шулай итеп элек кошлар сайрап торган гаҗәеп матур бер табигать почмагы тиз арада җансыз, күңелсез, ташландык бер чокыр – чакырга әверелә. Мондый күңелсез хәлләрне булдырмаска мөмкин бит.

Авылыбызның яме, җирнең җаны булган чишмәләребез барыбызга да газиз, кадерле. Авылыбыз бик матур урында урнашкан.Мондый матур урынны борынгы бабаларыбыз озак эзләгәннәр. Алар теләсә кайсы урында төпләнмәгәннәр. Авыл булып утыру өчен якында гына урманы, болыны, инеше, салкын чишмә чыга торган җайлы калкулыклары булган урын кирәк булган.

Авылның иң газиз бер өлеше итеп, яратып халык чишмәләргә ягымлы исемнәр дә кушкан: Изгеләр чишмәсе, Якуб бабай чишмәсе, Ерак чишмә, Күз чишмәсе, Якты чишмә..

Һәр чишмәнең үз тарихы, үз моңы, үз агымы, үз юлы бар. Бер ише шарлап ага, тавышы еракларга ишетелә,икенчеләре исә әкрен генә үзенә юл ала. Өченчеләре, җир куеныннан кайнап, ургылып чыга. Җир куеныннан көмеш балдаклар чыгарып ургылучы чишмәләр кемгә генә кадерле түгел икән? Безнең балачагыбыз, гүя, шуннан башлана, яшел чирәмле чишмә юлы безгә олы тормышка юл күрсәтә. Чишмәләр кайнап чыгуын без һәрвакыт үзебезнең йөрәк тибешендә тоябыз.

Чишмәләр, газиз чишмәләр! Минем туган авылымда чишмәләр бик күп. Чишмә буенда кичке уеннар оештырыла, кичәләр үтә. Шат, моңлы җырлардан, дәртле бию көйләреннән чишмә тирәсе яңгырап тора. Бу чишмә яшьләрне таныштыра, кавыштыра. Элекке заманнарда бу урында елга буйлап әрәмәлекләр сузылган булган. Анда шомырт, карлыган, гөлҗимеш, балан агачлары үскән. Боларның барысыда кеше өчен, кешеләрнең бәхете өчен табигать тарафыннан бүләк итеп бирелгән.

Ә менә аерым тукталышны “Якуб бабай” чишмәсенә ясыйсым килә. Татар Икшермәсе авылына Арташ ягыннан кергәндә, авыл башындагы юл янәшәсендә бер кабер кала.Озак еллар кечкенә калкулык булып торган әлеге каберне 1983нче елларда шул авылда яшәүче Мәхмүт абый чардуган белән әйләндереп ала һәм чистартып, буяп тора. Бу изге эшкә Икшермәдә яшәүче башка кешеләр дә кушыла. Хикмәт шунда - каберлекнең тарихы бик гыйбрәтле һәм тирән мәгънәгә ия.

-Өлкәннәр әйтүе буенча, Татар Икшермәсе авылында Якуб исемле кеше яшәгән, - дип сөйли, Камилә әбинең килене Светлана ханым, - Һәм ул 25 еллык патша хезмәтенә алына. Хезмәтен үтәп кайтканда Якубның авылда бер туганы да калмый. Ул патша хезмәтеннән батырлыклары өчен медаль белән кайта, аны горурланып тагып йөри. Ә медальгә тәре сурәте

төшерелгән була. Авыл халкы Якубның тәреле медаль тагып йөрүен кабул итеп бетерә алмый, диненә хыянәт итүдә гаепли.

Икшермә авылыннан ерак түгел, елганы чыгып, кырны узгач, Әбде авылы урнашкан. Авылында элек-электән урыслар яшәгән. Авылдашларының кырын карашына түзә алмаган Якуб шунда барып урнаша. Авылына килеп- китеп йөри, әнинең әтисе Зариф бабайларда кунып чыккан вакытлары да булган. Шулай бер килүендә, язгы ташу чорында, Икшермәдә вафат була. Ләкин авыл муллалары аның җәсәден татар зиратына җирләргә рөхсәт бирми. Ике якны тоташтыручы күпер өзелгәнлектән, Әбде ягына да алып чыга алмыйлар. Әбде авылы руханилары, ташу беткәч, үзебезгә алып кайтырбыз, тау өстенә куеп торыгыз, дип киңәш итәләр. Шулай итеп, Якуб бабайның җәсәде Татар Икшермәсе авылы тау башында җирләнеп кала. Язгы ташу төгәлләнгәч, каберлек турысында, тау астында чишмә бәреп чыга. Әбде побы халыкка, менә күрдегезме, юкка рәнҗеткәнсез, бу кешегез изге күнелле кеше булган,-ди. Шуннан әлеге кизләү халык телендә Изге Якуб бабай чишмәсе дип йөртелә башлый. Тәреле медаль Дәүләт исемле солдатка да бирелгән була. Якуб бабайдан аермалы буларак, ул медален тагып йөрми, йорт нигезенә күмеп куя. Шуңадырмы, әлеге нигездә яшәүчеләр гомер иткәндә тынычлык тапмый. Утыз еллар элек шушы нигезгә яңа йорт салган кеше тәрене табып нигездән алып куя, шуннан соң нигезгә тынычлык иңә. Медальгә Кавказдагы батырлыклары өчен диелгән була.

Каберлек турысындагы тау астыннан бәреп чыккан чишмә, изге күңелнең күмелеп калмавын хәтерләтә. Кизләүнең сихәте турында да мәгълүматлар бик күп. Күзенә ак төшкән, чүп кергәннәр дә, буыннары сызлаучылар, борын-тамак авыртучылар да шушы кизләү суын эчеп, юынып шифа алганнар.

Халык сөйләве буенча тагын бер дәлил бар, Олы Арташ һәм Чәбия Чүрчи авыллары арасында элек үпкә, сөяк авырулары диспансеры эшләгән. Анда төрле шәһәрләрдән килгән тәҗрибәле табиблар дәвалаган. Авырулар Россиянең ерак шәһәрләреннән, әйтик Ленинградтан ук килгәннәр. Безгә күрәзәчеләр диспансерга бару юлында, кабер турысыннан агып чыга торган чишмә бар, шул чишмәнең суын эчеп дәваланырга куштылар, дип килә торган булганнар. Димәк, шул елларда ук чишмәнең дәвалау үзлеге булуы беленгән.

Ә бит чишмәнең моңарчы, башка кизләүләр кебек "өе"дә юк иде. Узган җәйдә шушы авылда туып үсеп хәзер Сабада яшәүче Хәсәншин Рушан белән тормыш иптәше Светлана кизләүне "өй"ле, юллы иткән.

- Әни шунда таң суы алырга йөргәч, суы сихәтле чишмә бар икәнен белә идем. Чишмәне төзекләндерү уе әнинең гел күңелендә йөргән. Әниебез намаз укый, ул әйтә икән, димәк, бу кирәкле эш. Авыл җирлеге башлыгы белән киңәшкәннән соң, чишмәне карарга булдык. Чишмә матурлау җаваплылык та өсти. Төзекләндерү вакытында ул юлын үзгәртеп, югалырга да мөмкин бит. Эш башлаганда курыктык, бик сак эшләргә тырыштык, булышучы егетләргә дә бик зур рәхмәт, - ди Светлана ханым.

Якуб бабай чишмәсе яныннан тагын бер чишмә ага. Анысын Якты чишмә дип йөртәләр. Якуб бабай чишмәсе төптән, тирәннән үк бәреп чыга, ә Якты чишмә тау итәгеннән агып тора. Шуңа исеме яктылык белән бәйләнгән икән. Үпкәләп калмасын дип Хәсәншиннар бу чишмәне дә матурлаганнар. Тирә-юне төсле рәшәткә белән әйләндереп алынган. Чишмә суы хәзер бизәкле самовар аша челтерәп агып утыра. Ике чишмә агымы буйлап чия, миләш, кура агачлары, декоратив куаклар, чәчәкләр утырткannar. Чишмәнең составын тикшертеп, янына бу турыда мәгълүмат та элеп куелган. Суның сыйфаты тиешле таләпләргә туры килә.

Ике чишмә дә юлчыларны алтынсу төс йөгертелгән ае белән каршы ала. Шифалы суын эчергәч тагын килегез дигәндәй челтерәп озатып кала. Әйе, юлаучылар арган җаннарына чишмә суыннан көч алып ял итеп китәләр. Сызылып аткан җәйге авыл таңын сәламләп каршылаган зәңгәр чишмәләр җыры кемгә генә якын түгел, кемнең генә күңел кылларына тәэсир итми кала икән?

Яшел яфраклар шаулап, болыннар, чирәмлекләр хуш ис бөркеп, чишмәләр чылтырап аккан ямьле урында яшәү нинди зур бәхет, нинди шатлык! Шуның өстенә, сәламәтлеккә дә нинди файдалы. Чишмә һәм коелар тирәсен һәрвакыт чистартып, тәртипкә китереп торыйк!

Җиләк – җимеш агачлары, куак, чәчәкләр утыртыйк! Туып үскән җиребезнең табигатен тагын да баетыйк, тагын да матурлатыйк.Туган табигатебезне, чишмәләребезне саклау-барыбызның да изге бурычы. Чишмәләр югалмасын, күмелмәсеннәр! Чишмәләрне саклап, яңаларны тапсак, авылларыбыз дә яшәрер, матурланыр, табигатьне, чишмәләре-безне саклауда үзебездән зур өлеш кертә алабыз. Карлар эреп, ямьле май урталарында табигать кочагына экскурсияләргә чыккан вакытта чишмәләрне чистарту, тирә-ягын тәртипкә китерү буенча эшне дәвам итәрбез. Киләчәктә без чишмәләребезне карап, чистартып торырга сүз бирәбез. Авылыбызда чишмәләр җыры тыңмасын! Һәр зур елга кечкенә чишмәләрдән башлана.Шуны онытмыйк!Туган якның җырчы чишмәләре бертуктаусыз челтерәп аксыннар!

Проект эшен башкарганнан соң без түбәндәге нәтиҗәгә килдек:

Безгә чишмәләр кирәк. Безнең әби-бабаларыбыз да кадерләгән, хөрмәт иткән аларны.Ләкин табигать байлыгы чиксез түгел.Аны соңгы чигенә кадәр сыкканчы,табигатькә һич кичекмәстән ярдәм итү юлларын уйларга кирәк.Киләчәк буыннар безне начарлык белән искә алмасын иде. Киләчәктә дә чишмәләргә юл өзелмәсен иде! Алар озын гомерле булсын, һәм кешеләрнең дә гомерләрен озынайтсыннар иде! Сакчыл караш белән алдагы көндә дә чишмәләрне саклыйк! Табигать белән кечкенәдән үк дуслашкан кеше - яхшы тәрбияле, мәрхәмәтле, бәхетле кеше ул! Туган төбәгенең матурлыгын күрә белүче, суның тәмен тоючы бала эти - әнисен , кардәш - ыруларын , тирә – юньдәге кешеләрне ихтирам итә. Туган йортын, туган авылын, туган ягын чын куңелдән яраткан кеше генә Ватанын ярата һәм кирәк вакытта , аны саклау өчен, үз – үзен аямыйча , көрәшкә күтәрелә . Аны исә чишмәләрдән , елга - күлләрдән башка күз алдына китереп тә булмый. Туган ил , туган нигез, ата-ана , туган авыл туган төбәктән , туган туфрак- суларыннан башлана. Онытмыйсы иде бу хакыйкатьне!

Менә шушындый бай тарихка ия “Якуб бабай” чишмәсе. Йомгаклап шуны әйтәсе килә: әлеге эшне башкару вакыт аралыгында мин чишмәнең барлыкка килү тарихын гына түгел, арабызда изге күңелле кешеләр барлыгында белдем. Алар ярдәме белән чишмә торгызылып, тарихы күтәрелде, без әби-бабайлардан калган изге сулы чишмә барлыгын белеп үсәбез. Бәлки без чишмәне бар дип тә белмәс идек.

*Кулланылган әдәбият исемлеге*


1. Гарипова Ф. Авылларны сөям җаным-тәнем белән. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1994

2. Саттаров Г.Ф. Атамалар дөньясына сәяхәт. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1992.

3. Әнәс Исхаков “чишмәләр иле син, Туган як!”. Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2001.

4.Саба таңнары газетасындагы басма: http://saby-rt.ru/news/kich%D3%99-b%D2%AFgen-irt%D3%99g%D3%99/izge-yakub-babay-chishmse


## ТУГАН АВЫЛЫМДАГЫ МИЛЛИ БӘЙРӘМ – СӨРӘН САЛУ


*Вәлиуллин Раяз, 3 нче сыйныф укучысы*

*Фәнни җитәкче: Аглиуллина Гөлнур Архаметдин кызы,ТР Кукмара районы Мәчкәрә авылы Н.А.Самигуллин исемендәге урта гомуми белем бирү мәктәбе*


Җырларда макталып җырланган минем туган авылым - Күкшел Кукмара районының зур авылларыннан санала. Ул район үзәгеннән 25 км ераклыкта урнашкан. Авыл үзенең киң асфальт урамнары, төзек, матур йортлары, игелекле, тырыш, һөнәрле халкы белән аерылып тора.

Авыл халкы бик тырыш. Инде колхозлар таркалып, кешеләр эшсез калсалар да, һәрберсенең үз тормышын алып барырлык һөнәре бар. Ә минем сезне аларның милли

традицияләре белән таныштырасым килә. Авыл халкы тырыш булгач, гел эшләп кенә тора дигән сүз түгел, күңелле итеп ял да итә белә.Мин менә шушы традицияләр белән кызыксына башладым. Шунлыктан китапханәгә керсәм дә, мәктәбебез музеена керсәм дә, газета-журналлар актарсам да, милли йолалар турында материал күрсәм, аларны җыя башладым. Шушы мәгълүматлар белән сезне дә таныштырам. Авыл халкының иң яраткан милли бәйрәмнәренең берсе , минемчә, Сабантуй. Сабантуй дисәм дә дөрес булмас, ул - Сөрән салу. Менә шуның турында сезгә сөйлисем килә дә инде минем.

Мин "Сөрән салу" темасы буенча тикшеренү эше башкардым.

Теманың өйрәнелү дәрәҗәсе

*Бүгенге көндә һәр кеше үз авылының милли традицияләрен киләчәк буынга калдырырга тырыша. Өлкән буын өчен бу бер дә шаккатырлык нәрсә дә түгел. Ә менә яшь буын әлеге үзенчәлекләрне тирәннән белеп бетерми, минемчә. Моның сәбәбе, авылның милли традицияләре турында материалларның тиешле дәрәҗәдә булмавы. Мондый материалның чикләнгән күләмдә генә булуы белән аңлатып буладыр. Шуңа күрә дә мин бу теманы сайлап алып өйрәнү начар булмас дип уйлыйм. Чөнки минем авылымның үзенә генә хас милли бәйрәмнәре күп. Авылдашларым матур яшәргә һәм гореф-гадәтләребезне югалтмый саклап калырга, киләчәк буынга тирән эз салып калдырырга тырыша. Кыскасы, мин эзләнгәндә моңа ышандым.*

*Эшемнең максаты:*

- *Борынгы гореф-гадәтләрне өйрәнеп, киләчәк буынга җиткерү.*

*Бурычлар:*

- *Төрле чыганаклардан гореф-гадәтләргә, милли йолаларга кагылышлы теоретик материалларны өйрәнү;*
- *Тема буенча материал җыю һәм анализлау;*
- *Авылыбызның өлкән буыннары белән очрашып, мәгълүматларны арттыру;*
- *Мәктәп укучыларының, авыл халкының бу бәйрәм, аның традицияләре турында хәбәрдәр булу дәрәҗәсен ачыклау;*
- *Үткәргән тикшеренүләр нигезендә проектның нәтиҗәсен ясау.*

*Методлары:*

- *Тикшеренү проблемасы буенча әдәбиятка һәм төрле чыганакларга теоретик анализ;*
- *Фактлар һәм практик материаллар җыю;*
- *Нәтиҗә ясау, чагыштыру һәм гомумиләштерү (булган һәм алган нәтиҗәләр буенча);*
- *Сораштыру, анкета үткәрү, интервью алу;*
- *Статистика һәм мәгълүматларны эшкәртү (диаграмма,таблица, математик мәгълүматлар).*

*Тикшерү объекты: татар халкының милли бәйрәме "Сөрән салу" (яки яулык җыю)*

*Тикшерү предметы: Мәктәп укучыларының бу бәйрәм, аның традицияләре турында хәбәрдар булу дәрәҗәсе;*

Гипотеза: Әгәр дә бу бәйрәм турында мәгълүмат күп булса, бәйрәмне күзаллау да тулырак була һәм аны үткәрү дә кызыклырак булачак. Ничек булса да кызлрга чигәргә өйрәнергә. Кызлар өчен бәйрәмгә хәзерлек шуннан башлана ич.

Мин бу бәйрәм традицияләрен саклау юнәлешендә нәрсәләр эшли алам.

Төп сораулар:

- *Нәрсә ул Сөрән салу?*
- *Бу бәйрәмне ничек үткәрәләр?*

Проект соравы:

- *Бу бәйрәмнең традицияләрен саклау юнәлешендә мин нәрсәләр эшли алам?*

Проектның продукты:информацион буклет, чиккән кулъяулык, чиккән сөлге.

I бүлек. Өлкәннәр бу бәйрәмне ничек үткәргән?

Тикшеренү эшенең этаплары.

Беренче этапта мәктәп укучылары өчен анкета эшкәртелде (кушымта1)

1.1.Анкета үткәрүнең максаты: укучыларның Сөрән салу бәйрәме, аның ничек үткәрелүе турында белүләрен тикшерү.

Тикшеренү өлешендә игътибарымны бигрәк тә бәйрәм турында заманча аңлауларына һәм фикерләүләренә басым ясадым. Минем яшьтәшләремнең бәйрәм, аның йолаларының саклануы, кыйммәте турында белүләрен тикшерәсем килде. Аның өчен мәктәп укучылары арасында анкета үткәрдем.

1.2.Аннан соң анкетага анализ ясадым. Аның нәтиҗәсен һәр сыйныфны чагыштырып түбәндәге диаграммада эшкәрттем.

Анкета сораулары.

| | |
|---|---|
| 1 | Нәрсә ул Сөрән салу? |
| 2 | Аны кайчан бәйрәм итәләр? |
| 3 | Ул бәйрәмнең йолалары турынданиләр беләсең? |
| 4 | Син бу бәйрәмне көтәсеңме? Яратасыңмы? |
| 5 | Бу бәйрәмгә синең гаиләң ничек хәзерләнә? |

Тикшерү нигезендә түбәндәге нәтиҗәгә килдем: укучылар бу бәйрәм турында яхшы беләләр. Ләкин әле мәгънәсен, асылын, кирәклеген аңлап бетермиләр. Менә шул нәтиҗә миндә Сөрән турында тикшеренү эшен башкарырга, аның турында күбрәк белергә, өйрәнергә һәм белгәннәремне иптәшләрем белән бүлешү теләге тудырды.

Өлкәннәр сөйләве буенча бәйрәм-йоланың тарихы.

Сөрәнгә чыгу

Сабантуй бәйрәме, элек-электән, бик борынгы заманнардан ук үткәрелә торган бәйрәмнәрдән санала. Язын сабан эшләре беткәч, халык азрак үзенә бәйрәм ясаган, күңел ачкан. Сабантуй бәйрәменә бүләк җыю бик күңелле булган. Әбием сөйләгәннәрдән чыгып шуны белдем: өй саен кереп, бүләк җыюны сөрәнгә чыгу дип атаганнар. Ә сөрәнче – сабан туена бүләк җыючы булган. Безнең якларда яшь киленнәр сөрәнгә бик матур чигелгән сөлге, ә яшь кызлар күз явын алырдай итеп чигелгән кульъяулык биргәннәр. Яшь киленнәрдән алган сөлге иң кыйммәтлесе булып саналган. Килен аны шушы йоланы истә тотып,үзенең бирнәсендәге иң матур бизәкле сөлгедән әзерләгән. Һәр хуҗа хатын сабантуйга бүләк чыгара торган булган. Әгәр дә бүләк җыючылар йортка кермәсә, хуҗалар үпкәли торган булганнар. Бүләк бирмәүчеләрне авыл халкы саранлыкта гаепләгән. “ Бүләгем – көрәшчегә”, “ чабышта җиңүчегә”, “ иң арттан килүчегә” дип атап бүләк бирүчеләр дә булган. Бүләкне алгач, юмарт хуҗаларны мактап: “ Сабирә апа сабантуйга чиккән сөлге бирде. Ура, ура,ура!”- дип кычкырып рәхмәт әйтә торган булганнар. Бүләкләрне яшьләр җыеп йөргән. Аларның берсе колга күтәргән, бүләкләрне шуңа элгәннәр, ә иң матур сөлге колга очында җилфердәгән. Гармун, җыр тавышы яңгырап торган. Ахырда бүләкләрен мөхтәрәм авыл картларына тапшырганнар. Ул бүләкләрне сабантуйда ярышта җиңүчеләргә биргәннәр.

Авылымда Сөрән салу хәзер ничек үтә?

Мәгълүмат этабы:

Икенче этапта без тема буенча информация җыйдык: интервьюлар алдык, өлкәнрәк яшьтәге кешеләр белән әңгәмәләр үткәрдек. Шулар нәтиҗәсендә мин бәйрәм, аның йолалары турында бик күп нәрсәгә төшендем.

Ә хәзер мин сезне хәзерге көндә авылымда үтә торган Сөрән салу (яки яулык җыю) йоласы турында җыйган материалым белән таныштырам. Бу материалда күренгәнчә, авылымда әле элеккеге йола онытылып бетмәгән дип әйтәсем килә. Мин үзем бәйрәм башлана торган урамда яшим. Шуңа күрә ел саен бу тамашаны карарга эти-әниемә ияреп чыгам. Миңа быел аеруча игътибарлы булырга туры килде. Кемнәр белән генә аралашмадым.

Караңгы җәйге төн. Сәгать төнге бер. Сәгать төнге бер булуга карамастан, авылның ник бер кешесе йокласын. Капкалар ачык, һәр кешенең ишегалдында өстәл тулы сыйнигъмәт

Барысы да сөрән салучыларны көтә. Җомгага каршы төндә бала-чагалар да, карткорылар да йокламый. Алай гына да түгел, авылдан шәһәргә күчеп киткәннәр дә олаулары белән төялеп кайткан.Менә монда да бер гаилә кунаклары.

Кукмара районы Күкшел авылында сабантуйга әнә шулай әзерләнәләр. Әлеге традиция Татарстанның бер генә авылында да сакланмаган. Сөрән салу инде ничә гасыр яшәп килүен күкшеллеләр үзләре дә белми. Әллә бу күрше мари авылыннан килгән горефгадәт, әллә ял итү галәмәтеме микән, билгесез.

Иң беренче аңлатмалы сүзлектән "сөрән " сүзенең мәгънәсен ачыклыйсым килде.

Сөрән – ярышларга өндәп, чакырып, аваз салып йөрү йоласы.

Сөрән салу – нәрсәгә дә булса өндәп, чакырып, кычкыру, аваз салу

Сөрәнче– сөрән салып, өндәп йөрүче.

Юк икән шул. Сөрәнчеләрнең тарихы бик еракка барып тоташа икән. Үзләренең җырлары, такмазалары, бүләк җыю алымнары бар. 78 яшьлек күрше бабае Гыйләҗетдинов Галыйп абзый сөрән салуны балачактан ук хәтерли. "Ата-бабалар бу йоланы безгә сеңдереп калдырган, бүген дә шулай дәвам итә. Нинди генә авыр заманнарда да аны тыя алмадылар, без дә үз вакытыбызда сөрән җыюда катнаштык", – ди ул.

Тимиров Нәкыйп абый: "Бу йола бик күптәннән, без кечкенә чаклардан ук үткәрелә инде. Аның әле ашарына да булмас иде. Өстәлдән барыбер йомырка, ипи төшмәде. Күп кеше кычыткан ашы пешерер иде. Тозлаган яшелчәне дә бары бәйрәмдә генә ашадык. Анысын күрше мари авылыннан алып кайтыр идек. Барыбер бик күңелле булды, бәйрәмне бетермәдек ", - дип, сөрән турында фикере белән уртаклашты.

Тыеп кара син аларны, әзмәвер егетләрне, диюем. Әнә авыл башында сәгать теле нәкъ төнге берне сукканда җыелдылар. Башына түбәтәй, өстенә ап-ак күлмәк, кара чалбар, аягына киез итек кигән, биленә чигелгән сөлге таккан егермеләп егет шаулатып бер биеп алды да авылның беренче өенә юл тотты.

Атлар иярләдеңме,
Тайлар йөгәнләдеңме,
Сабантуе җитә диеп,
Бүләк әзерләдеңме?

Теманың актуальлеге: әйләнә- тирәбезгә күз салсак, төрле чүпләрнең- полиэтилен пакетларның, чипсы, кириешкидан, төрле соклардан бушаган савытларның, консерв банкаларының, майонездан бушаган чиләкләрнең, пластик кашык, чәнечкеләрнең, тәлинкә, стаканнарның, конфет-печеньедан бушаган тартмаларның аунап, чәчелеп ятуы бер дә күңелле күренеш түгел. Табигатьне чүпкә баткан килеш күрү авыр, ул бит елый, сыкрана, ә без кешеләр аны ишетә һәм тыңлый белмибез. Экологик проблемалар турында, әйләнә - тирәбезнең көнкүреш калдыклары, завод-фабрикалардан чыккан калдыклар белән пычрануы турында күп сөйлиләр. Без дә әйләнә-тирә дөнья дәресендә көнкүреш калдыкларының табигатькә нинди зыян китерүләре турында өйрәндек. Алар арсыннан пыяла һәм пластик шешәләрнең, пакетларның меңәр ел дәвамында җирдә ятсалар да череп таркалмаулары, яндырган очракта да һавага зарарлы матдәләр бүлеп чыгарулары турында мәгълүмат алдык. Әле кечкенә булсам да, мине экологик проблемалар бик борчый. Мин үсеп җиткәнче һәм аннан соң табигать белән ни булыр? Суларга саф һава, чиста күк йөзе, эчәргә чиста су калырмы? Кичекмәстән кешеләрнең чүплекләргә карата карашларын үзгәртергә кирәк, минемчә. Ә мин, башка кирәге чыкмаган, бер тапкыр кулланылышта булган савытлардан уенчыклар ясап карарга булдым, ә аннан соң сыйныфташларымның да мондый “чүпләрне” куллануга карата фикерләрен беләсем килде.

Югарыда санаганнардан чыгып эшемнең проблемасын билгеләдем:

-бер тапкыр кулланышта булган материалларны куллану мөмкинлеген өйрәнү һәм аны сыйныфташларыма да өйрәтү.

Шулай итеп, эшемнең максаты барлыкка килде: ташландык материаллардан төрле кул эшләнмәләре эшләү һәм сыйныфташларымның да ташландык материалларны куллануга карата фикерләрен өйрәнү.

Югарыда китерелгән максаттан чыгып, бурычлар билгеләдем:

1. Ташландык материалларны куллану мөмкинлеген өйрәнү.
2. Ташландык материаллардан төрле кул эшләнмәләре эшләү.
3. Башлангыч сыйныф укучылары арасында ташландык материалларны икенче тапкыр куллану мөмкинлеге турында сораштыру үткәрү.

Мин иң элек ташландык материаллардан нәрсәләр ясап булуы турында “Көмеш кыңгырау” газеталарыннан һәм “Тылсымлы куллар”, “Мастерилка” журналларыннан, китаплардан укыдым, интернет чыганакларда эзләндем.Үземнең нинди уенчыклар ясаячагымны планлаштырдым һәм материаллар тупладым. Бер тапкыр кулланышта булган савытлардан төрле сувенирлар, йортны, бакчаны, ишегалдын бизәү өчен төрле эшләнмәләр, кошлар өчен җимлекләр ясап була икән. Моның өчен фәкать тырышлык һәм фантазия генә кирәк! Үз кулларың белән ясаган әйберләр матур да, күп чыгым да сорамыйлар. Дусларга, туганнарга бүләк итәргә менә дигән бүләк тә булып торалар (Кушымта 2).

Мин үземнең фантазиям һәм барлык мөмкинлекләремне кулланып, майонездан бушаган чиләктән куян ясарга булдым. Ул бик җиңел ясала. Куян ясау өчен кирәкле булган материаллар (фото 1): ак төстәге майонездан бушаган чиләк, колаклар өчен ак төстәге картон кәгазь, чәчләре өчен мамык диск, күзләр өчен зәңгәр һәм кара төстәге төсле кәгазьләр, иреннәр һәм борын өчен кызыл төстәге төсле кәгазь, койрык өчен ак төстәге мамык, куянның мыекларын сызу өчен кара төстәге маркер, аслык өчен ак төстәге синтепон мамык, кайчы, канцелярия пычагы, ябыштыру өчен клей.

Иң башта куянның баш өлешен әзерлибез (фото 2): колакларын ак төстәге картоннан кисәбез. Зәңгәр төстәге һәм кара төстәге төсле кәгазьләрдән күз формасы ясап кисәбез, зәңгәр өлеше зуррак, ә карасы кечкенәрәк булырга тиеш. Зәңгәр кәгазь өстенә карасын куеп ябыштырабыз. Иреннәрен һәм борынын кызыл төстәге кәгазьдән, чәчләрен мамык дисктан кисәбез. Ә хәзер инде әзер булган өлешләрне чиләкнең капкачына ябыштырабыз. Мыекларын кара маркер белән сызып куябыз (фото 3). Колакларын урнаштыру өчен чиләкнең өске кырыеннан 2 см озынлыкта тишем кисәбез һәм колакны шул кисемгә тыгабыз, койрыгын ябыштырабыз (фото 4). Әзер куянны мамык аслыкка куябыз (фото 5). Куяныбыз әзер, нинди матур куян килеп чыкты! (фото 6)

Мин башлангыч сыйныф укучылары арасында сораштыру үткәрдем. Анда 13 укучы катнашты. Аларның барысына да өчәр сорау белән мөрәҗәгать иттем (кушымта 2).

Мин үземнең тикшерү эше барышында шуны ачыкладым: барлык укучылар да ташландык материалларның нәрсә икәнен, аларны төрле эшләнмәләр ясаганда кулланып булу хакында һәм шулай итеп табигатьне саклап калу мөмкинлеге турында беләләр.

Мин иптәшләремә төрле эшләнмәләр ясаган вакытта әле тагын бик күп төрле материалларны кулланып булу мөмкинлеге турында сөйләдем. Сәдәфләрдән, капрон колготкилардан, носкилардан, бияләйләрдән, җепләрдән, төрле конфет кәгазьләреннән, чәйдән, конфет-печеньедан бушаган тартмалардан, шешәләрдән, шнурлардан бик күп эшләнмәләр, бәйрәм өчен костюмнар ясап булу турында аңлаттым.

Мин майонез чиләген кулланып ясаган куянымның иптәшләремә бик ошаганын ачыкладым. Сыйныфташларым үзләре дә технология дәресендә ташландык материаллардан төрле уенчыклар ясадылар. Шулай итеп, минем гипотезам расланды.

Йомгаклау

Нәтиҗә: һәр кеше табигатьнең чисталыгын саклауга үзеннән зур өлеш кертә ала. Без кулланган ашамлык тартмалары, бер тапкыр кулланышта булган пластик савытлар чүплекләрдә, тирә-юнебездә аунап ятмасыннар иде. Алардан без бик күп төрле әйберләр

ясый алабыз. Шуның белән өйләребезне, бакчаларыбызны, ишегалларыбызны ямьләндерәбез, акчаны да янга калдырабыз, табигатьне пычранудан да саклый алабыз.

Мондый әйберләрне кулланып уенчыклар ясаган вакытта фантазия һәм күзаллау да үсә, шулай ук әйләнә-тирәгә карата сакчыл мөнәсәбәттә булырга да өйрәнәбез, вакытыбызны да файдалы үткәрәбез.

Проект өстендә эшләгәндә бик күп нәрсәләргә өйрәндем: максат куярга, план буенча эшләргә һәм тишерүләр үткәрергә. Алга таба мин үз алдыма бер тапкыр кулланышта булган материаллардан дусларыма бүләк итү өчен сувенирлар ясауны максат итеп куям.

*Кулланылган әдәбият*


1. Давыдова Г.Н., Детский дизайн. Поделки из бросового материала. 2006. 80 с.
2. Коноплёва Н.П. Вторая жизнь вещей / Н.П. Коноплёва.- М., 1993.
3. “Көмеш кыңгырау” газеталары, 2017 ел
4. “Мастерилка” журналы, 2015 ел
5. “Тылсымлы куллар” журналы, 2017 ел
6. Смакова Р.А. Весёлые поделки/ Р.А. Смакова.– М., 2004.
7. http://www.podelki-rukami-svoimi.ru/top-15-idei-podelki-iz-brosovogo-materiala/


## КАЛЬЦИЙНЫҢ ОРГАНИЗМГА ӘҺӘМИЯТЕ


*Кашапова Ралинә, 3 нче сыйныфукучысы.*
*Фәнни җитәкче: Зарипова Розалия Фаил кызы,*
*ТР,Саба районы Явлаштау урта мәктәбе*


Максат:организмга кальцийның әһәмиятен ачыклау

Тикшерү объекты: кальций

Бурычлар:

1. организмга кальцийның әһәмиятен ачыклау;
2. организмга кальций җитмәгән очракта ни булачагын күзәтү;
3. кальцийга бай ризыкларны барлау.

Без балалар шаян-шук, уйнарга яратабыз. Шатланабыз, ә кайчагында елашып та алабыз. Менә бер көнне уйнаган вакытта бер бәхетсезлек очрагы булды бит әле. Минем кулым сынды. Әти-әнием тиз арада больницага алып бардылар. Тәҗрибәле врачлар миңа ярдәм күрсәтте. Сөякләргә кальций кирәк, ул булмаган очракта сөяк тиз сына дип аңлаттылар.Күбрәк кальцийлы ризыклар ашарга куштылар. Ә аның организмга нинди әһәмияте бар соң? Мин шуны тикшерергә булдым.

Кальций (Calcium), Ca, Мнделеев таблицасындагы химик элемент. Кальций кеше оргнизмына бик кирәк. Сөякләрдә кальций 90% ка кадәр исәпләнә, әмма ул сөяк өчен генә түгел, ә бәлки бөтен организм өчен дә эшли. Ул сөякләрне формалаштыру һәм ныгыту турында кайгырта. Үсү һәм тешләрне саклау өчен кирәк. Бөтен организмның күзәнәкләрен тергезергә булыша. Нерв системасын «тукландыра», нервыларга тузарга ирек бирми.

Кальций нинди продуктларда бар?

Тавык йомыркасы, шулай ук солы, карабодай боткасы, борчак, фасоль, чикләвек, көнбагыш, әфлисун, йөзем дә кальцийга бай.

Җәй көне шпинат, яшел суган, петрушка, салат үләне, кыяр, чөгендер, кишер, ак баш кәбестә һәм чәчәк кәбестә күп ашарга тырышыгыз. Кальций шулай ук виноград һәм абрикоста да күп.

Чәчәк кәбестәнең яфрагын ташларга ашыкмагыз: анда кальций кәбестәнең «чәчәк» өлешендәгегә караганда күбрәк. Яфракларны чистартыгыз, юыгыз да, гади кәбестәне кулланган төсле файдаланыгыз.

Кальций сөттә һәм сөт продуктларында бик күп. 100 г голланд сырында ул 1040 мг, плавленый сырда — 740, эремчектә — 150, сөт һәм йогыртта 120 мг тирәсе исәпләнә.

Практик өлеш

Организмга кальций җитмәгәнлектән нинди үзгәрешләр була икән? Моның өчен тикшерү эше үткәреп карарга булдым.

Беренче тәҗрибә:

Ике тавык йомыркасы алдым. Чөнки аның кабыгы составында кальций бар.

1 йомырканы гади сулы банкага, ә икенчесен уксуслы банкага салабыз. Ни өчен уксусга? Чөнки кальций әче тирәлектә бик яхшы таркала.

Берничә сәгатьтән соң сулы башкадагы йомыркада үзгәреш күренмәде, ә уксусга салынганында күбекләр барлыкка килде. Мин аларны 7 көн күзәттем һәм уксусга салынган йомырканың кабыгы резин рәвешенә килде.

Димәк, тешнең эмалендә йомырка кабыгы кебек үк кальций булмаса, юкара.

Икенче тәҗрибә:

Сөяк 90 % кальцийдан тора. Ә кальций булмаса ул нинди булыр иде икән? Минем моны бик беләсем килде. Бу тәҗрибәм өчен мин тавык сөяге алдым.

Шулай ук аны уксус салынган банкага салдым. Банканы капкач белән каплап 7 көнгә куйдым. Бу вакыт эчендә сөяктәге кальцийны уксус тарката. 7 көн үткәч, сөякне алып карадым. Сөяк йомшарган, бөгелә.

Димәк, сөяктә кальций булмаса, ул йомшак, тиз сынучан була икән.

Йомгаклау

Бу тәҗрибәләрне үткәргәч, мин шундый нәтиҗәгә килдем. Тешләр сау-сәламәт, сөякләребез нык булсын өчен кальцийга бай ризыклар кулланырга һәм составында кальций булган теш пасталары белән чистартырга кирәк. Киләчәктә мин бу кагыйдәләрне үтәргә тырышачакмын. Һәм иптәшләремә дә киңәш итәм.

*Кулланылган әдәбият исемлеге*

1. http://polzaili.ru/rol-kalciya-v-organizme-cheloveka-istochniki-normy-osobennosti/
2. http://www.zdortegi.ru/kalciy-v-organizme/
3. https://pdoctor.ru/health/kalcij-v-organizme-cheloveka.html

## ТАТАР ХАЛЫК АВЫЗ ИҖАТЫ

*Латыпов Динар, 2 нче сыйныф укучысы,*
*Фәнни җитәкче: Сафаргалиева Фирдания Миннемулла кызы*
*ТР Саба муниципаль районы муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*
*"И.С.Башкиров исемендәге Завод-Ныртлы урта мәктәбе"*

Мин әдәби уку дәресендә “Халык әйтсә-хак әйтә” дигән бүлек белән танышканчы, аның ни өчен шулай аталганын белергә теләдем. Төрле чыганаклардан эзләгәннән соң, халык иҗатының күпкырлы һәм бай милли иҗат икәнен аңладым. Кайбер әкиятләрнең, табышмак, җыр, такмак, санамыш, мәзәк, бишек җырларының авторы бер генә кеше түгел, ә бик күп кешеләр була. Бу әсәрләр бик борынгы чорлардан ук телдән телгә күчеп килгән, шуңа күрә аларны халык авыз иҗаты дип йөртәләр. Миңа бу тема бик мавыктыргыч булып тоелды. Иптәшләрем белән табышмаклар әйтешү, төрле әкиятләр тыңлау, татар халык уеннары уйнау, санамышлар, тел шомарткычлар өйрәнү өчен бер җыелма туплау теләге туды миндә. Һәм мин иптәшләрем белән файдаланыр өчен уңайлы булган татар халык иҗаты материаллары тупланган лэпбук ясап карарга булдым.

Эшемне үтәгәндә үз алдыма түбәндәге максат һәм бурычлар куйдым.

Максат: Халык авыз иҗаты турында тулырак өйрәнеп, аларны туплап лэпбук ясау.

Бурычлар:

Халык иҗат әсәрләрен кызыксынып уку

Укыганнарны истә калдыру, иптәшләрем белән уртаклашу

Проектның этаплары:

1.Әзерлек этабы: лэпбукның темасын сайлау, проблема кую, проект буенча материал җыю

2.Төп этап: татар халык иҗаты әсәрләре белән танышу, аларны туплау

3.Йомгаклау этабы: татар халык иҗат әсәрләре тупланган кисәле, ачыла торган матур тематик китап- лэпбук ясау

Көтелгән нәтиҗәләр:

1. Халык иҗатын кызыксынып укый башлау, аның төрләрен дәресләрдә, дәрестән тыш эшчәнлектә куллану

2. Сөйләм байлыгын арттыру, сөйләм телен үстерү

3. Лэпбук ясау сәләтен үстерү.

Эшемне башкарганда, "Балалар фольклоры" , "Энҗе чәчтем-энҗе җыям"җыентык-китапларыннан, мәктәп әдәби уку дәреслекләреннән, интернет челтәре чыганакларыннан файдаландым.

Төп өлеш

Лэпбук ул – үз кулларың белән эшләнгән зур булмаган папка. Аңа бирелгән тема буенча кирәкле материаллар тупланган. Яки кулдан ясалган кисәле, ачыла торган матур китап. Аны беренче мәртәбә Америкада кулланганнар. Инглиз теленнән тәрҗемәсе(lap-колени,book-книга, «наколенная книга») җыелма күрсәтмә һәм таратма материаллар тупланган китап.

Лэпбук нәрсә өчен кирәк?

- Теманы яхшырак аңлау һәм истә калдыру өчен,
- үткәнне кабатлау өчен бик яхшы алым,
- мәгълүмәтне җыяргаһәм тупларга өйрәтә,
- сөйләмне, фикерләү сәләтен устерергә булыша,
- эшләгәндә күзәтүчәнлекне арттыра, чагыштырырга, анализ ясарга, гомумиләштерергә һәм нәтиҗә ясарга өйрәтә

Лэпбук нәрсәдән тора? Кисәләр, китапчыклар һәм мәгълүмәтләр җыелмасыннан.

Лэпбук ясау өчен кирәк материаллар: җирлек өчен картон,ак һәм төсле кәгазьләр, кайчы, клей, карандаш, төсле карандашлар,фломастер,скотч, шаблоннар,степлер һәм , әлбәттә, фантазия.

Эшнең тәртибе.

Иң беренче эш итеп мин макет ясадым.

Минем лэпбук 8 элементтан тора. Элементларның шаблоннарын сайлап һәр төргә кисәләр эзерләдем.Мәгълүмәтләр җыеп , аларны шушы кисәләргә урнаштырдым.

Тырышлыгымны һәм фантазиямны эшкә җигеп лэпбукны ясый башладым.

Җирлек өчен картон әзерләдем, аны тышладым, халкыбызның милли бизәкләре белән бизәдем. Урта битнең өстенә фигуралы чәчәк-конверт эченә темамны , халык иҗаты әсәрләрен язып чыктым. Алга таба халык иҗатының төрләренә тукталдым.

"Мәкальләр"– халыкның тормыш тәҗрибәсен туплаган кыска, тирән мәгънәле төгәл җөмләләр ул. Мәкальнең төп мәгънәсе "сөйләп,әйтеп бирү"дигәнне аңлата.Төп максаты – фикер әйтү.Туган ил, хезмәт, ата-ана, тәрбия һәм башкалар турында мәкальләрне без бик яратып укыйбыз.

"Табышмак" – зиһен ачкычы, күмәк эчендә bерең әйткәннең мәгънәсен икенче кешедән чишелешен таптыру өчен башкарыла торган фольклор. Борын-борыннан табышмакның җавабын тиз табучы кешене тапкыр кеше дип йөрткәннәр. Табышмак әйтешеп уйнау безгә бик охшый. Мин мәкаль белән табышмакларны миләш-китапчыкларга тупладым.

«Сынамышлар» - сынамышның төп максаты– киләчәкне хәбәр итү. Сынамыш ул халыкның күпьеллык күзәтүләре нәтиҗәсендә туган әйтелмә. Ел фасыллары, хайваннарның, кошларның, бөҗәкләрнең үз-үзләрен тотышлары, үләннәр, куаклар, агачларның төрле билгеләре, табигать күренешләре белән бәйле сынамышлар бар.

Каен суы күп акса, җәй яңгырлы була.

Томан төшсә, артыннан явым була.

Кыш көнендә урман җилсез шауласа, буран була.

Ябалак кар яуса, аннан соң һава җылы, юеш булыр.

Сынамышлар, бүген безнең өчен, халыкның рухи дөньясын, аның табигатькә карашын яхшырак аңларга ярдәм итүләре белән кыйммәтле.

«Тизәйткечләр» - авазларны дөрес әйтергә өйрәнүдә -иң нәтиҗәле алым. Бу уенны тәнәфесләрдә дә, дәресләрдә дә мавыктыргыч итеп оештырабыз. Мин сынамыш белән тизәйткечләрне гармошка элементы белән күрсәттем.

«Әкиятләр» - халкыбызның авыз иҗатында иң бай һәм мавыктыргыч төрләренең берсе булып тора.

Татар халык әкияләрен өч төркемгә бүләләр: хайваннар турында әкиятләр, тылсымлы әкиятләр һәм тормыш-көнкүреш әкиятләре.

Хайваннар турындагы әкиятләрнең төп геройлары – кыргый җанварлар, йорт терлекләре, кошлар . Хайваннар турындагы әкиятләрдә төрле хайваннарга төрлечә бәя бирелә: ат – һәрвакыттагыча, эшчән һәм кешенең якын дусты; кәҗә – тапкыр, бүре – усал һәм аңгыра, арслан – көчле, төлке – хәйләкәр, аю – авыр табигатьле. Хайваннар турындагы әкиятләрдә иң еш очрый торганы - төлке. Аннан кала аю һәм бүре. Төлке барлык әкиятләрдә дә диярлек хәйләкәр, алдакчы, ялагай итеп сурәтләнә. Аю, бүре – тупас, ахмак буларак тасвирлана.

Тылсымлы әкиятләрнең үзәгендә уңай образ – батыр, акыллы, кулыннан һәртөрле эш килә торган егет образы тора. Халыкның көче һәм аның тапкырлыгы менә шул егет образында бирелә. Ул патша, дию пәриләре, аждаһалар яки башка шуның кебек кара көчләргә каршы көрәштә һәрвакыт җиңеп чыга. Аңа акыл иясе картлар, курку белмәс дуслары, тапкыр һәм сөйкемле сылу кызлар, төрле серле әйберләр, кешегә ияләшкән кыргый хайваннар булышалар.

Тормыш-көнкүреш әкиятләрендә ялкаулык, саранлык, куркаклык һәрвакыт кешеләрдәге иң начар сыйфатлар буларак күрсәтелә.

Бу кесәгә халык әкиятләре, алардан өзекләр җыйдым, рәсемнәр ясадым. Аларны кайсы әкияттән икәнен танырга һәм сөйләп бирергә кирәк.

“Уеннар” . Укудан, өй эшләреннән әз генә бушасак, урамга чыгып төрле уеннар уйнарга бик яратабыз без. Уеннар - халык иҗат җимеше ул. Аларны халык уйлап чыгарган. Безнең борыңгы бабаларыбыз да балачакта матур-матур уеннар уйнап үскәннәр. Алар да, әкиятләр, җырлар кебек үк, буыннардан - буынга күчә –күчә шомарганнар, аларга яңа кызыклы вакыйгалар, сүзләр, хәрәкәтләр өстәлгән. Шулай итеп уен мавыктыргыч, кызыклы булып киткән.

«Бишек җырлары» - бишектәге баланы тирбәтеп йоклатканда, юатканда җырлана торган җырлар. Мин аларны балалар журналларыннан табып китапчык итеп ясадым һәм бишеккә салдым.

«Санамышлар» - уенны башлап җибәргәндә балалар арасында әйтелә торган үзенә бер төр тезем сүзләр. Кайбер санамышлар эчтәлекле була. Еш кына гадәти булмаган, уйлап чыгарылган сүзләр дә очрый. Алары да гармошка итеп ясалып, аерым конвертка тутырылды.

Йомгаклау. Шушы кечкенә генә лэпбукка балалар өчен кызыклы материалар тупларга тырыштым. Әлеге папканың уңайлы ягы шунда – аны яңа кызыклы материаллар белән тулыландырырга була. Папканы тулыландыру өстендә эш алып барам. Иптәшләремә дә кызык булып китте. Алар миңа теләп булышалар. Без үзебенең милләтебезне онытмыйча, милли гореф-гадәтләрне дәвам итәргә, фольклор әсәрләрен сөйләмебездә кулланырга тиешбез.

Халык иҗатын өйрәнү – безнең зиһенебезне баета, дөньяга карашыбызны киңәйтә, тел байлыгыбызны, белемебезне үстерә, тарихыбызны аңларга ярдәм итә.

*Кулланылган әдәбият*


1. Минһаҗева Л.И. Балалар фольклоры. Казан: «Хәтер» нәшрияте,2009 ел
2. Ягъфәров Р.Ф. Татар халык уеннары.Казан:"Мәгариф" нәшрияты, 2002 ел
3. Закирова К.В., Низамов Р.А.Көч һәм рух тамырлары. Казан:"Мәгариф" нәшрияты, 1998 ел
4. Ф.Ш.Гарифуллина, И.Х.Мияссарова.Әдәби уку дәреслекләре. Казан:"Мәгариф-Вакыт" нәшрияты, 2013 ел


## МИЛЛИ КУРЧАК ТЕГҮ


*Мингазова Илүзә, 4нче сыйныф укучысы*
*Фәнни җитәкче: Мулюкова Иркә Рәшит кызы*
*Т РКукмара муниципаль районы "Пычак урта мәктәбе" Арпаяз авылы филиалы муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесе*


Проектның бурычлары:

*1.Үстерүче бурычлар:*

- кирәкле материалны сайлап ала белү күнекмәсен үстерү;
- коммуникатив күнекмәләрне үстерү;
- укучыларның сөйләм телен үстерү;
- шигъри әсәрләрне сәнгатьле уку күнекмәсен үстерү;

-компьютер техникасы куллану күнекмәсен үстерү.

*2. Өйрәтүче бурычлар:*

- укучыларның курчак һәм милли киемнәр турында белемнәрен киңәйтү;
- "курчак" сүзе нәрсә аңлатканлыгын, аның файдасы нидәлеген ачыклау;

*3. Тәрбияви бурычлар:*

- борынгы милли киемнәргә сак караш, гуманлы мөнәсәбәт тәрбияләү.

*4. Практик бурычлар:*

- электрон презентацияләр ясау, милли киемнәр һәм курчаклар турында шигырьләр, табышмаклар җыентыгы булдыру, укучылар ясаган рәсемнәрдән, укучылар ясаган эшләрдән күргәзмә оештыру;
- ата – аналарны чакырып проектның презентациясен уздыру.

Эзләнү методлары:

1. Әдәбиятне өйрәнү һәм анализлау.
2. Интернеттан, мәктәп һәм авыл китапханәләреннән информация эзләү.
3. Күзәтү, чагыштыру.
4. Эзләнүле әңгәмә.
5. Курчак театрларына экскурсия.

Проектның нәтиҗәсе (продукты): электрон презентацияләр, милли киемнәр турында шигырьләр, табышмаклар җыентыгы, укучылар ясаган рәсемнәрдән, укучылар ясаган эшләрдән күргәзмә.

Проектны чынга ашыру этаплары:

*Проблема сайлау.* Дөньяда бик күп төрле проблемалар булырга мөмкин. Һәм аларны чишү юллары да була. Иң беренче чиратта әйбәтләп уйлап эш итәргә кирәк.

Менә минем дә алдымда проблема тора. Мин үземә үз кулларым белән технология дәресеннән курчакларым төрләре янына милли татар кызы тегәргә җыенам. Ул курчак матур һәм сыйфатлы булып чыгар дип уйлыйм.

*Фикерләрне ачыклау.* Менә инде ниһаять, мин үз проблемамны чиштем. Мин курчакларым төрләре янына милли татар кызы тегәргә булдым.

Бу курчакны теккәндә кирәк булачак эш коралларын һәм материалларны өйдән алып килергә туры килер.

Мин үз эшемнең матур булып чыгуын телим һәм моның өчен тырышачакмын.

Милли киемнәр хәзерге тормыш-көнкүрештә кулланылмый, аларны без сәхнәләрдә генә күрә алабыз.

Элекке заманнан ук халык һәрчак матурлыкка, сәнгатькә омтылып яшәгән. Оста куллы хатын-кызларыбыз мавыктыргыч кул эше белән шөгыльләнгәннәр. Үзләренә һәм туганнарына милли киемнәр теккәннәр. Бөтен тырышлыкларын куеп зәвык белән затлы калфак-түбәтәйләр, матур эскәтер-сөлгеләр, күкрәкчә-алъяпкычлар чиккәннәр.

Элекке заманда, фабрикалар барлыкка килгәнче, кешеләр тукымаларны да үзләре тукыганнар. Һәрбер авыл гаиләсендә диярлек туку станогы булган. Бу эш бик күп көч һәм вакыт таләп иткән.

Башта җитен яисә киндер үстергәннәр. Урып-җыйганнан соң, орлыкларын сугып алганнар. Каты сабаклардан йомшак йон ясар өчен, җитенне озак кына суда яисә кар астында тотканнар. Шуннан соң яхшылап киптереп таяклар белән сукканнар. Татар фольклорында “Киндер суктым” дигән җыр да бар.

Йомшаган киндерне язып тараганнар һәм элгәннәр. Туку станогында тукыма, сөлге, паласлар тукыганнар. Бизәкләп туку өчен киндерне төрле төскә буяганнар. Татар милли киемнәрендә ак, кызыл, яшел, зәңгәр төсләр өстенлек итә.

Татар халкының милли киемнәрен хәзер без күбрәк Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле концертларында, театр сәхнәләрендә һәм музейларында гына күрәбез.

1934 елда нигез салынган Татар дәүләт «Әкият» курчак театры - Татарстанның иң өлкән театрларыннан берсе.Русиянең иң зур тарихлы тулы хокуклы курчак театрларыннан санала. Бүгенге көндә театр – Татарстанның курчак театры сәнгатенең Русиядә һәм чит илләрдә танылган үзенчәлекле үзәге булып тора.

1934 елда элекке чиркәү бинасында «Беренче дәүләт интернациональ курчак театры» исеме белән ачыла. Спектакльләр ике телдә: татарчаһәм русча уйнала. Беренче тамашалар: «Петрушка – октябрят», «Кызыл Петрушка», «Песи һәм Лешка».

Театрны оештыручылар : режиссер Сергей Мерзляков,артистлар Мәрьям Хисамова, Мария Язвина, Фуат Таһиров, Вәли Гафаров, Борис Рычков, Сара Вәлиуллина, Зинаида Устинова, Рокыя Хәбибуллина. “Үткәнен белмәгәннең киләчәге юк”, ди халык мәкале.Ә халык әйтсә , хак әйтә. Шуны истә тотып, курчакларыбызда халкыбызның үзенчәлекле милли киемнәре белән тегүне оештырганнар .

Элекке заманда татар хатын-кызының милли киеме бер төсле иркен күлмәктән торган. Еш кына ул киң бөрмәләр яки бала итәкләр белән бизәлгән. Гадәттә, бер халыкның да милли күлмәкләре аерым гына киелмәгән. Татар киеменә күлмәк өстеннән авыр ефәк бәрхет тукымадан тегелгән һәм төрле декоратив тасма белән бизәлгән камзул хас.

*Калфак* - татар хатын-кызларының алиһәсе дәрәҗәсенә күтәрүче гамәли сәнгатебезнең үзенчәлекле сәнгать әсәре. Татар хатын-кызларының гадәти баш киеме бигрәк тә күп төрле һәм үзенчәлекле. Кызлар баш киеме хатыннарныкыннан аерылган. Бала чакта кызларга ситсыдан тәкыя ясаганнар. Аның маңгай өлешенә вак тәңкәләр, төймәләр һәм корт башлары тегелгән була. Тау ягы керәшен татарлары (Мәлки төркеме) такыя тоташ тәңкәләр, мәрҗәннәр белән бизәлгән баш киемен тәшкил итә. Аны буйга җиткән кызлар кигән. Калган төркемнәрдә кызлар калфак киеп, маңгайларына ука-чачак бәйләгәннәр.

Калфакның төрләре хәйран күп. XIX йөзнең урталарына кадәр зур, чуклары аркага (яки иңгә) төшеп торган капчык калфаклар була. Аларны төрле төстәге җептән яки тукымадан ясаганнар. Ак җептән бәйләнгән озын калфаклар барлык төркем кызларына да хас була. Ләкин керәшен татарларында бу төр кызлар калфагы бигрәк тә тотрыклы булган. Мондый озын калфакны башка кигәндә аның кырыен бер-ике кат бөкләгәннәр һәм өстән

маңгайга ука-чачак бәйләгәннәр. Ә менә кара бәрхеттән яки сатиннан чигеп эшләгән озын калфаклар Мишә буе көрәшен татарларында XX йөз башларында да саклanган.

XVIII-XIX гасырлар белән чагыштырганда, калфакларның формасы, бизәлеше һәрвакыт үзгәрә тора. Элек йомшак трикотаж яки бәйләнгән чигүле ак калфаклары популяр булган. Аларны зур, башка киелә торган итеп теккәннәр яки бәйләгәннәр. XVIII гасыр калфаклары бизәлешендә синель ябыштыру һәм "тырнак алмалау" ысулы белән өчпочмакка бөкләнгән кечкенә тукыма кисәкләре кулланып күптөсмерле чәчәк элементлары ясалган.

Шуннан соңгы чорларда чуклары аркага кадәр төшеп торган "капчык" калфаклар булган. Алар ,бәрхеттән тегелеп, алтын ука белән чигелгәннәр.

XIX гасыр урталарында кечерәк "капчыклы" хәтфә калфаклар барлыкка килгән. Еш кына андый калфакларны яулык яки ефәк шәл астыннан киеп йөри торган булганнар.

Әкренләп каты кырпулы зур калфак кечерәя, декоратив каптырмага әверелә. XIX гасырдан алып бүгенге көнгә кадәр калфакларның бизәлешенә.ука белән беррәттән,ак,сирәк кенә төсле энҗе,сәйлән бөртекләре кулланып чигү керә бара

Бүлмәнең аерым бер төр эш башкарырлык итеп җиһазландырылган өлешен *эш урыны* дип йөртәләр.

Кул эшләре өчен эш кораллары һәм җайланмалары тиешенчә итеп куелган өстәл кирәк.

Эш урынында бары тик хәзер эшләнәсе эш өчен кирәкле кораллар, җайланмалар һәм эшкәртеләсе детальләр генә булырга тиеш. Барлык эш өстәлдә башкарыла, эшкәртү детальләрен күз алдында тоту уңай.

*Эш төгәлләнгәчниләр үтәргә:*

➤Энә кадагычтагы энәләрне кабат санарга, эшли ➤башлаганчы булган санын барларга;

➤Эш урынын җыештырырга.

Төп сызымны модельләү юлы белән курчакның төрле силуэтларын табарга мөмкин. Курчакның киеме ни дәрәҗәдә сыланып торуы үлчәмнәргә өстәмәләрдән бәйле.

Курчак гәүдәсе өлешләренең төп контурларын-баш, гәүдә, кул һәм аяк өлешен тегү сызымның нигезен тәшкил итә. Сызым өлге буенча төзелә. Өлге гәүдә профиленең иң нык үзгәргән урыннарында урнашкан вертикаль һәм горизанталь сызыклар җыелмасыннан тора. Әйбернең киңлеге һәм озынлыгы буенча гомуми үлчәмен челтәр билгеле.

Кешенең гәүдәсе симметрияле булганлыктан, сызым әйбер киңлегенең ярты өлешенә генә төзелә.

Проект эшенең барышын язмача сурәтләү.

Өлгеләрне интернет челтәреннән эзләп алдым, аны принтер аша чыгартып кистем. Материалга куеп төшердем(һәрбер өлгене икешәр экземпляр)

Тукыма эченә калган материалны тутырдым һәм һәрбер өлешне аерым тектем. Ахырдан барысын тоташтырдым.

*Үз-үзеңә бәя бирү.* Шулай итеп, мин үз максатыма ирештем дип уйлыйм. Без халкыбызның гамәли бизәлеш сәнгате, төрле чигү ысуллары белән тагын да якынрак таныштык. Алар ярдәмендә без, чигү серләрен өйрәнеп, төрле әйберләр бизәргә керешербез, дип ышанасым килә. Элекке заманнардагы кебек, кызларыбыз хәзердән үк үзләренә бирнә әзерли башларлар, әби-бабаларына бүләкләр чигәрләр дип уйлыйм.

Татар милли киемнәре, кызганычка каршы, халык мәдәниятенең үзенчәлекле төре буларак, безнең бүгенге тормышыбызда бары тик сәхнәдә һәм музейларда гына сакланып килә. Форсаттан файдаланып, без үзебезнең мәктәп бинасында урнашкан туган як музеена кереп чыктык һәм "Мәктәптән тыш эшләр үзәге"ндә булдык, анда үзләре теккән берничә төр милли татар бию киеме мисалларын күрдек.

Безнең ут күршеләребез булган удмурт халкын, менә ичмасам, үрнәк итеп куярга була. Үзен удмурт дип санаган кешенең һәрберсендә дә өендә милли киеме бар. Иң мөһиме: ул киемнәр сандык саклап кына ятмый, ә төрле удмурт милли бәйрәмнәрен үткәргәндә, туйларда, дини йолалар вакытында һәрдаим киелеп тора. Шулай да, соңгы вакытта, без

татарларда да әзрәк сөенечле күзәтүләр ясарга була: шәрык һәм төрек культурасының илебезгә көчле йогынты ясавы нәтиҗәсе буларакмы, башка сәбәпләр аркасындамы, татар халкының милли бизәнгеч әйберләре гадәти тормышыбызга кире кайта. Әйе, татар хатын-кызлары матур-матур бизәкле, төсле ташлы, милли орнаментлы алкалар, беләзекләр, муенсалар тага башладылар. Казаныбызда милли киемнәр тегү, чигү буенча шәхси эшмәкәрләр кибетләр ача башлады. Модельерлар да татар милли кием элементларын, нәкышларын үзләренең эксклюзив киемнәренә кертә башладылар: подиумнарда мондый үрнәкләрне дә күрергә бик мөмкин. Милли татар киемнәре, бизәкләре чит ил кунаклары тарафыннан да теләп кабул ителә.


*Кулланылган әдәбият.*

1.Бикбулатова М.З. Чигәргә өйрән.-Казан:Тат.кит.нәшр.,1970.-67б.

2.Сергеева Н.Г. Тылсымлы энә.-Казан:Тат.кит.нәшр.,2001.-24б.

3.Сергеева Н.Г.Әбиемнең сандыгы.-Казан:Тат.кит.нәшр.,1995.-32.

4. Интернет-чыганаклар.


## ГАИЛӘМДӘ ЧӘК-ЧӘК ПЕШЕРҮ - БУЫННАРДАН КИЛГӘН МИРАС


*Миннәхмәтова Резеда, 2нче сыйныф укучысы*

*Фәнни җитәкче: Минәхмәтова Әнисә Хәким кызы,*

*ТР, Мамадыш районы«Түбән Ушмы урта гомуми белем мәктәбе»*


Без әйләнә-тирәне өйрәнү дәресләрендә милли ризыклар турында сөйләштек. Милли ризыклар – алар бик борынгы заманнардан алып бүгенге көнгә кадәр килеп җиткән, татар халкына гына хас ризыклар. Аларны безнең әниләребез, әбиләребез бүген дә пешерә. Төрле гаиләләрдә бер үк төрле ризыклар төрле-төрле рецептлар, төрле тәртип-кагыйдәләре буенча әзерләнә. Алар - гаилә традицияләренең бер өлешен тәшкил итәләр һәм буыннардан буеннарга күчеп киләләр.Минем дә, гаиләмдәге ризыклар пешерү традицияләре турында күбрәк белү теләгем уянды. Гореф-гадәтләрне белү, йолаларны саклау гаиләләрне берләштерә, ныгыта. Мине чәк-чәк бик кызыксындырды. Чөнки минем әбием янына “Сәкинә апа, чәк-чәк пешереп бир әле, “ – дип бик еш киләләр! Ни өчен әбием башкаларга да пешерә, чәк-чәкне, башкалар пешерә белмиләрме? Ни өчен укытучы апабыз аны иң затлы милли ризык дип атады икән? Без әлеге сорауга җавап табарга теләдек.

Максат: чәк-чәк пешерү серләренең гаиләбезгә буыннардан килгән мирас булын ачыклау.

Бурычлар:

- милли ризыклар турында өйрәнергә;
- чәк-чәкнең килеш чыгу тарихын белергә;
- чәк-чәкнең бүгенге көндә тоткан урынын күзәтергә;
- гаилә тарихын барларга;
- әбиемнең чәк-чәк пешерү серләренә төшенергә;
- әбием белән бергә чәк-чәк пешереп карарга.

### *1. Татар милли ризыклары төрләре*

Татар халкы бик борынгыдан ук аш-су әзерләргә оста булган, тәмле ашлар пешергән. Милли ашларның үзенчәлеге халыкның тормыш рәвешенә бәйле булган. Татар халкы үз милли ашлары белән бик бай һәм бөтен дөньяга үз ризыклары белән мәшһүр. Татар аш-су осталары бик күп төрле ашамлыклар уйлап тапканнар. Халкыбыз бик борынгы заманнардан ук иген иккән, шуңа күрә күбрәк арыш, бодай, борчак, арпа, солы оныннан төрле ризыклар

пешерү гадәти күренеш саналган. Бәйрәм табынына чәк- чәк, пәһләвә, кош теле, гөбәдия, талкыш кәләвә куйганнар. Аларны безнең әниләребез, әбиләребез бүген дә пешерә.

*2. Нәрсә соң ул чәк-чәк?*

Интернеттан алган мәгълүматкә караганда, чәк-чәк - ул камырдан һәм балдан ясалган татлы ризык. Ул татарларның һәм башкортларның милли ризыгы санала. Чәк-чәкнең бик күп төрләре билгеле. Татарстанның Казан тирәсендәге районнарында яшәүче татарлар, гадәттә, чәк-чәк пешерсә, республиканың көньяк-көнчыгыш өлешендә урнашкан Әлмәт, Азнакай, Ютазы, Лениногорск, Бөгелмә, Баулы кебек ерак төбәкләрендә бавырсак пешерәләр. Әлеге сый Башкортстанда да бик популяр. Бавырсак, чәк-чәк дип тә, төш дип тә атап йөртәләр әле аны. Казан чәк-чәгеннән аермалы буларак, бавырсак эре итеп пешерелә.

Чәк-чәкне икенче төрле «Татарстанның баллы вәкиле» дип атарга мөмкин. Бал белән беркетелгән түгәрәкләр, эре һәм токмач юкалыгында, киселгән сызыклар торт, конус, пироженое формасына җыела һәм озак саклана. Чәк-чәк республиканың каршы алучы ризыгы булуы юкка гына түгел. Аны пешерү серләре һәм ысуллары буыннан-буынга килә.

*3. Чәк-чәкнең килеп чыгуы турында чын әкият.*

Чәк-чәк каян килеп чыккан? Ничек ул татар халкының милли ризыгы булып киткән? Борын-борын заманда, Бөек Болгар дәүләтендә бөек ханы яшәгән. Хан улының туена чит илләрдән кунаклар чакырга уйлаган. Туй табынына куяр өчен дөньяда булмаган ризык пешертергә теләгән. Ул бөтен Болгар иленә хәбәр салган:

- Кем дә кем, бердәнбер улымның туй табынына шундый ризык уйлап тапса, ул ризык бик ансат әзерләнсә, ул ризык бик озак бозылмыйча сакланса, тәме айлар үткәч тә бозмаса, мәргәннәр аны атларыннан төшмичә дә ашый алса, илебез данын еракларга таратса һәм һәр тантананы бизәсә, шуңа бик күп байлык һәм мәртәбә бирәчәкмен, - дигән - ризык туклыклы да булсын, ерак илләргә күчтәнәч итеп җибәрерга ярасын, дип өстәгән. Барлык ханлык халкы озак баш ваткан. Нинди генә татлы ризыклар ясап карамаганнар алар. Ләкин берсе дә ханның теләкләрен канәгатьләндермәгән.

Көннәрдән бер көнне бер көтүче, хатыны пешергән чәк-чәкне алып килгән. Йомырка, он һәм балдан ясалган әлеге ризык хан күнеленә хуш килгән. Шул көннән бирле, чәк-чәк һәр бәйрәмдә табын түрендә иң затлы ризык булып калган. Бүгенге көндә дә чәк-чәк иң тәмле сый-нигъмәт булып табыннарыбызны бизи.

*4. Чәк-чәк безнең көннәрдә*

Бүген чәк-чәк татар халкының иң затлы, иң күркәм ризыгы булып тантаналы чараларны ачу символы булып тора. Бәйрәмнәрне чәк-чәктән башка күз алдына китереп тә булмый. Ул һәр туй мәҗлесендә булмый калмый. Чәкчәкне кияү йортына кәләш һәм аның әти-әниләре алып килә. Юка гына җиләк-җимеш кагына төргән чәкчәк туйда хөрмәтле сыйлардан санала.

2008 елда III Бөтендөнья татар яшьләре форумында “Чәк-чәк” бәйрәмен үткәрү карары кабул ителгән. Мондый бәйрәм ел саен, илебезнең төрле почмакларында үткәрелә. Татарстаннан тыш, әлеге бәйрәм Оренбург, Ижау, Ташкент, Төмән шәһәрләрендә уздырыла. Бәйрәмдә милли ризыгыбызны пешерүчеләр белән танышу, чәк-чәк пешерү серләрен үзләштерү, чәк-чәк пешерүчеләр арасында бәйгеләр уздыру карала. Болар сәхнәдән җыр-бию белән уралып алып барыла.

Казан шәһәрендә Чәк-чәк музее эшләп килә. Музейда чәк-чәк тарихын, аны пешерү серләре белергә мөмкин. Шулай ук, анда эшләп килүче сәүдә почмагында чәк-чәкнең төрле төрләрен сатып алып, сыйланырга була.

*5. Гаиләм тарихы һәм чәк-чәк*

Безнең гаиләбез бик зур. Гаиләбездә өч буын вәкиле яшибез: әбием, этием-әнием, ике абыем һәм мин. Гаиләбездә төрле тәмле ризыклар тешерәбез. Ризыкларны әнием яки әбием пешерә, ә мин аларга булышам. Мин инде милли ризыкларның нәрсәләр булуын яхшы беләм. Әнием итле-бәрәңгеле яки дөге һәм җимешле бәлешне тел йотарлык итеп пешерсә, әбием данлыклы чәк-чәк пешерү остасы. Без чәк-чәкнең бик тәмле ризык икәнен беләбез һәм аны әбием һәр туган көнгә, ураза, корбан яңа ел, сабан туе бәйрәмнәренә һәрчак пешерә.

Гаиләмдә ханнар заманыннан калган рецептлар саклануын белгәч, мине чиксез горурлык хисе биләп алды. Минем башыма мең дә бер сорау килде. Мин аларны гаиләдәгеләргә яудырдым:

- *Минем әбием дөньядагы иң оста чәк-чәк пешерүчеме?*
- *Ул аны кайдан өйрәнгән?*
- *Ни өчен чәк-чәкне бар кеше дә пешерә белми?*
- *Бу һөнәргә мин өйрәнә аламмы?*

Әнием миңа гаиләбез тарихын сөйләде. Габделрәхим бабам Әсхабҗамал әбиемне (Кушымта, 1 нче рәсем) Арташ авылыннан алып кайткан. Әсхабҗамал әби аш-суга, аеруча чәк-чәк пешерергә бик оста булган. Аларның өч уллары, өч кызлары булган. Кызганыч, каты авырулардан, ачлыктан аларның биш балалары үлгән. Бары Миннәхмәт исемле төпчек уллары гына исән калган.  Ерак бабам Миннәхмәт (Кушымта, 2 нче рәсем) ерак әбием Зарифа (Кушымта, 3 нче рәсем)  белән 1937нче елда гаилә корганнар.  Әсхабҗамал әби Зарифа әбигә үзенең мирасын – чәк-чәк пешерү серен калдырып бакыйлыкка киткән. Аларның ике уллар дөньяга килгән: Динмөхәммәт белән Гыйлемхан (Кушымта, 4 нче рәсем). (Гыйлемхан – минем бабам – әтиемнең әтисе була ). Улларына гына тигез ата-ана канаты астында үсәргә насыйп булмаган. Миннәхмәт бабам Бөек Ватан сугышында үлеп калган. Зарифа әбием, ятим калган ике улын, үзе генә тәрбияләп үстергән. Ерак әбием бик уңган-булган кеше булган. Мирас итеп алган чәк-чәк пешерү осталыгы аңа, тирә-юньдә дан тотырга ярдәм иткән. Аны атка утыртып, хәттә башка авылларга да, чәк-чәк пешерергә алып китә торган булганнар.  Әбиемнең кызлары булмаган. Бер-бер арты уллары өйләнгән. Төп йортка килен итеп Гыйлемхан бабам Сәкинә әбиемне (Кушымта, 5 нче рәсем) алып кайткан. Зифа буйлы, чибәр, сабыр холыклы кыз, эшкә дә батыр булган. Гел кайнанасы тирәсендә бөтерелгән. Чәк-чәк пешерү серенә дә төшенеп аны үзе дә пешерә башлаган. Сәкинә әбиемнең дә кызлары булмаган, алар Гыйлемхан  бабам белән баһадирдай ике ул үстергәннәр. Өлкән уллары - Марат абый. Кече уллары  Илсур - минем әтием (Кушымта, 6 нчы рәсем)  . Сәкинә әбием дә җитез, чая киленнәргә кайнана булган.  Әлбәттә, чәк-чәк пешерү серләрен аларга ачкан. Бүген  Сәкинә әбиенең ике килене дә (зур килен – Әлфия апа, кече килен – минем әнием (Кушымта, 7 нче рәсем) чәк-чәк пешерә беләләр. Шулай да әле, Сәкинә әбиемә тиңләшә алмыйлар!

Әбием пешергән чәк-чәкне татып караучылар исләре китеп аның пешерү тәртибен язып алалар. Өйләрендә пешереп караганнан соң: “Сәкинә апа, син аның бөтен серен ачып бетермисеңдер, мин пешергән чәк-чәк син пешергән кебек килеп чыкмый,” – диләр.

Бу сорауга әнием җавап бирә: “Әбиең аны “бисмиллаһ”ын әйтеп, бик теләп, бар күңел җылысын салып пешерә. Шуңа, ул пешергән чәк-чәкләр бик тәмле килеп чыга.”

Әбием: “Чәк-чәк пешерергә китап укып өйрәнеп булмый. Ничек пешергәннәрен үз күзең белән карап торырга кирәк. Аннан үзең пешереп карарга. Беренче такырдан гына чыкмый әле ул!  Чәк-чәк пешерү серләренә эшли-эшли төшенәсең. Иң мөһиме, “миннән булмый,”- дип кул селтәмәскә, бик тырыш булырга кирәк,” – ди.

Авылыбызда зур спорткоплекс эшли. Анда республика, рәсәйкүләм спорт ярышлары үткәрелә. Илебезнең төрле почмакларыннан килгән кунакларны каршы алырга, әлбәттә инде, әбием чәк-чәк пешереп бирә. Әбием кулыннан төшкән бу горурлыгыбызны кемнәр генә авыз итмәгән: Кырым, Дагестан, Чечнядан килгән кунаклар. Севастопль, Украина, Себер, Үзбәкстан, Таҗикстан, Мәскәү якларына күчтәнәч булып киткәннәрен  кемнәр генә татып калмаган, мактаган да әле үзен. Әбием пешергән чәк-чәкләрне телевизордан карап, газета битләреннән күреп горурланып утырам.  Алтын куллы, милли җанлы, үрнәк  минем әбием!

## 6. *Әбиемнең чәк-чәк пешерү серләре*

Әбием чәк-чәк пешерә башласа, мин тизрәк аның янына йөгерәм. Минем тизрәк чәк-чәк пешерү серләренә өйрәнәсем килә.

Йомыркаларны яхшылап болгатасы; аңа чеметеп тоз, сода остәп, бик йомышак камыр басасы. Аны ярты сәгатькә, тастымал каплап тынычлыкта калдырасы. Аннан камырны

кечкенә кисәкләргә бүлеп, 2 см калынлыкта җәясе. Җәйгән камырдан 3см киңлекәге тасмалар теләсе. Тасмалардан 2см киңлектә чәк-чәк кисәсе.

Зур табакка сыек май салып кайнатырга куясы, аңа бераз туң май да өстисе. Кайнап чыкканын көтмичә чәк-чәк камырын салып, әкерен генә болгатып пешерәсе. Чәк-чәкне кызган майга салырга ярамый! Пешеп чыккан камырны тишекле чүмеч белән җыеп аласы. Майны уттан алып, бераз суытып аласы. (Салкын суга утыртып, кар өстенә куеп та суытырга мөмкин. Бераз кызулыгы беткәнче генә, гел суынып беткәнче түгел.)

Тагын камыр салып пешерәсе, тагын суытып аласы. Кискән камырлар пешерелеп беткәнче шулай кабалана.

Камыр әзер булгач бал эретелә. Дүрт өлеш балга бер өлеш шикәр комы салып кайнатабыз. Балны савыт белән салкын суга тамызып карыйбыз; балдан куык ясалса, димәк ул – әзер. Кайнар балны чәк-чәк өстенә сибәбез һәм барысы да тигез баллансын өчен тиз-тиз болгатабыз. Яссы тәлинкәгә чәк-чәк ясап өябез.

*Йомгаклау*

Эшебезгә нәтиҗә ясар вакыт җитте. Эш барышында без:

- татар милли ризыклары турында өйрәндек;
- чәк-чәкнең килеш чыгу тарихы турында кызылы легендага тап булдык;
- бүгенге көндә чәк-чәкнең милләтебезнең йөзек кашы булуын дәлилләдек;
- гаиләбез тарихын өйрәндек һәм борынгы болгар бабаларыбыздан калган кыйммәтле хәзинә – чәк-чәк пешерү осталыгы, ядкарь булып гаиләбездә сакланганлыгын белдек;
- әбиемнең чәк-чәк пешерү серләрен ачтык. Әбием чәк-чәге, аны “бисмиллаһ”ын әйтеп, бик теләп, бар күңел җылысын салып пешергәнгә, рецептында буыннар җылысы салынганга бик тәмле, татлы, авызда эрүчән була икән.

Шулай итеп, мин хәзер әбимнең чәк-чәк пешерегә кайдан өйрәнгәнен белдем (Кушымта, 9 нче рәсем). Ул - ерак әбиемнәрдән килгән мирас. Әсхабҗамал әбиемнең кызлары булмаса да аның чәк-чәк пешерү осталыгын киленнәре Зарифа әбием, Сәкинә әбием һәм әнием дәвам иткән. Бишенче буында гына кыз бала - мин дөньяга килгәнмен. Димәк, без аны иң кадерле мирас итеп, күз карасы кебек саклап, үзебездән соң килгән буыннарга да чәчми-түкми җиткерергә тиешбез.

*Кулланылган әдәбият:*

1. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. Казан. “Матбугат йорты” нәшрияты, 2005.
2. Татар халык ашлары. Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1987.
3. http://beznen.ru/basma/2013-18/donyasina-uch-itep-yashedem/

http://shahrikazan.com/tt/2015-02-03-12-35-12/item/15189-ch%D3%99k-ch%D3%99k-t%D2%AFgel-%E2%80%93-bavyirsak.html

*Чыганаклар:*

1. *Миннәхмәтова Сәкинә әбием истәлекләре (1948нче елда туган)*
2. *Габдрәхимов Динмөхәммәт бабай истәлекләре (1938 нче елда туган)*
3. *Габдрәхимова Нурсаимә әби истәлекләре (1940 нче елда туган)*
4. *Әнием (Миннәхмәтова Әнисә) сойләгәннәрдән (1975 нче елда туган)*
5. *Китапханәче (Габдуллина Гөлсинә Димөхәммәт кызы) сөйләгәннәрдән*
6. *Гаилә фотоархивы*

## ЭТНИЧЕСКИЕ МОТИВЫ В СОВРЕМЕННОМ КОСТЮМЕ

*Мусина Илюза, ученица 10 «а» класса*
*Научный руководитель: Ярмухаметова Альбина Габдулбаровна*
*МБОУ “СОШ п.г.т.Кукмор №3” Кукморского района РТ*

Наш мир идёт далеко вперёд. Меняются люди, меняются технологии, меняются взгляды на жизнь, меняются вкусы и вместе с ними и наша одежда. Если оглянуться, можно увидеть тысячи разных нарядов: ярких, красочных, модных, стильных. Современная одежда

сегодня – это не просто только платья, юбки или пиджаки с куртками, которые нужны, чтобы закрыться от холода и посторонних глаз. Одежда – это прежде всего стиль и отражение внутреннего мира, помимо тепла и уюта; одежда- это символ нашего положения в обществе; одежда- открытое послание окружающему человечеству. А красивая, молодежная одежда – это еще и постоянный источник эстетического удовольствия и наслаждения, отличного настроения и способ повысить себе самооценку. Но среди огромного количества разных видов одежды, к сожалению, вряд ли можно увидеть людей в их национальной одежде.

По национальности - я татарка и мне всегда интересовало история своего края, своего народа: их жизнь, обычаи, традиции. Но к тому же я увлекаюсь шитьем. И я решила соединить все свои умения, навыки и интересы для создания коллекции в которую бы входила частичка из национальной одежды татар. И этой частичкой стали этнические мотивы . Сегодня этнические мотивы всё больше привлекают внимание дизайнеров своей красочностью и яркой индивидуальностью. Многие ведущие модельеры с удовольствием используют элементы национального и народного творчества при создании своих линий одежды. Поклонников моды от такого креатива в полном восторге. Для одних это предмет гордости за богатое наследие своей нации, для других - интерес к познанию новых культур и традиций.

Так зародилась идея создания коллекции «Этнические мотивы в современном костюме».

**Краткая формулировка задачи**

- Сшить коллекцию одежды, учитывая мои возможности и потребности.
- Научиться применять свои навыки, умения и знания в ходе всей работы.
- Воспитать эстетический вкус, терпение.
- Оформить и защитить свой проект.

**История национального татарского костюма**

Национальный татарский костюм прошел длинный путь исторического развития. Костюм – наиболее яркий «индикатор» национальной принадлежности, воплощение понятия об идеальном образе представителя своей нации. Сливаясь с физическим обликом, он рассказывает об индивидуальных особенностях человека, его возрасте, социальном положении, характере, эстетических вкусах. В разные периоды истории в костюме сплетались моральные нормы и историческая память народа с естественным стремлением человека к новизне и совершенству.

Татарский костюм представляет собой уникальную систему народного художественного творчества, включавшую в себя изготовление тканей, сложных и богато орнаментированных головных уборов, производство различных видов обуви, высокохудожественных ювелирных украшений. Все элементы системы выступали согласованно, сочетаясь друг с другом по форме, цвету, материалу изготовления, образуя единый стилевой ансамбль. Наиболее ярко национальные особенности в одежде прослеживаются в женском костюме, в силу эмоциональности женщин и их внутренней потребности к красоте. При всей цветовой экзотичности он не выпадает из общей мировой тенденции моды: стремление к приталенному силуэту, отказ от больших плоскостей белого цвета, широкое применение продольного волана, использование в отделке объемных цветов, позументов, драгоценностей. Для одежды татар характерен традиционный трапециевидный силуэт с «восточной» насыщенностью цветов, обилие вышивок, применение большого количества украшений. Издавна татары ценили мех диких зверей – черно-бурой лисицы, куницы, соболя, бобра.

**Золотое шитье в народном костюме**

Вышивка - один из древнейших и популярных видов женского изобразительного искусства. По мнению профессора Н.Воробьева, развитие этого вида искусства было связано с затворничеством женщин, которые редко выходили из дому и свой досуг использовали для рукоделия. В отличие от русских, украинцев, мари и других народов татары не только применяли вышивку в одежде, но и украшали предметы бытового назначения: полотенца, салфетки, скатерти, покрывала и оконные занавески, *намазлыки* (коврики для молитв).

Традиционный классический комплекс народного татарского костюма формировался с 18 века, однако характерный свой облик получил веком позже, вбирая в себя множество видов декоративного народного творчества: ткачество, вышивку, золотое шитье, художественную обработку кожи. Золотое шитье украшало камзолы, тюбетейки, калфаки, праздничную обувь. В народном

декоративно-прикладном искусстве татар - именно в вышивке - ярко проявился расцвет цветочно-растительного орнамента. Золотошвейный промысел объединил сотни мастериц. Татарские вышивальщицы работали по заказам как на внутренний, так и на внешний рынок. Их изделия продавались в торговых рядах знаменитого "Сенного базара" в Казани, на ярмарках Москвы и Нижнего Новгорода, Ирбитской и Сеитовой слобод. Изделия казанских мастериц вывозились за пределы Поволжья.. В качестве основы для золотного шитья применялись бархат, велюр, парча,сукно, хлопчатобумажные ткани хлопчатобумажные ткани,изредка применялась и привозная тонкой выделки кожа.

**Дизайн-спецификация**

Экокожа – это нанесенный на хлопковое полотно (тканевое, трикотажное или нетканое) слой полиуретана. При нанесении его на основу не нужно применять никаких добавок – пластификаторов. Синтез полиуретана протекает значительно сложней, чем у поливинилхлорида. Именно поэтому такой искусственный материал не выделяет никаких полимеров, что дало материалу его «экологическое» название.

Благодаря тканой основе и пористому полиуретану экокожа отлично пропускает воздух — лучше, чем натуральный аналог. Если слой полимерного покрытия увеличивают, ткань получается более прочной, но и более жесткой. Характерный рисунок поверхности, текстуру, во всем подобную натуральной, экокожа получает после обработки давлением.

Отличить искусственный материал от натурального очень просто: на изнанке экокожи отчетливо видна ткань.

Преимущества этого уникального искусственного материала заключаются в следующем:

- Рисунок идентичен натуральной коже;
- Процесс её производства менее затратный, гуманный и экологически намного менее опасен, чем изготовление кожи из животного;
- Может выпускаться различных размеров – цельным куском, что является просто невозможным при использовании натурального материала (например, для производства мебели). Возможность шить изделия без швов делает всё более эстетичным и практичным; много вариантов цвета;
- невысокая гигроскопичность, что улучшает эксплуатационные характеристики готовых изделий из кожи;
- морозостойкость и устойчивость к солнечным лучам – не «дубеет» и не выгорает; эластичность и податливость, легко режется, шьётся;
- долговечность и практичность; устойчивость к истиранию;Подходит для использования аллергикам, у которых есть реакция на мех и кожу животных.
- Именно удивительная схожесть экокожи с оригиналом и её следующие преимущественные свойства делают её отличной альтернативой натуральной коже.

*Экологическое*: экологически чистое по следующим причинам:

1. Материалы выполены из экологических чистых материалов.

2. Материалы приобретаются строго по расходу используемого, нет отходов от производства, а значит не загрязняется окружающая среда.

*Эстетическое:* эстетичность требует высокого качества исполнения работ, с соблюдением сочетания материалов. Я постаралась выполнить свой комплект красиво и в хорошем качестве.

Маркетинговое*:* наша продукция отличается не только качеством, но и низкой себестоимостью, если бы я захотела продать свою работу, то предложила бы следующие цены:

Модель 1-2500 руб.

Модель 2-2500 руб.

Модель 3-3500 руб.

**Самоанализ**

Шить одежду для самой-это большая ответственность, ведь его нельзя выполнить торопясь, неаккуратно. Мне потребовалось много усилий и времени, чтобы создать коллекцию « Этнические

мотивы в современном костюме». На мой взгляд, она получилась очень красивой, изысканной, индивидуальной и неповторимой.

Игла и нитки были моими помощниками. Первые шаги по изготовлению коллекции я делала при помощи ручных стежков, а после проверки выполнялись швы на швейной машине. Мне пришлось вспомнить виды швов, способы их обработки. Если у меня плохо получалось, приходилось переделывать, чтобы получился хороший результат. В ходе шитья я воспитала терпение, умение стоять на своем. Я научилась шить новые виды одежды, такие как брюки, блузка и жакет,которые отказались непростыми, но к счастью моя учительница помогла и подсказывала некоторые моменты. Я думаю, что в целом проект получился хороший. Я довольна своим результатом и смотрю на него с удовольствием и восхищением. Надеюсь, председателям жюри она тоже понравиться. Также при работе я использовала дополнительную литературу,за счет чего узнала много нового и интересного.

Стоит отметить и то, что во время изготовления коллекции, я не раз обращалась к национальному костюму татарского народа. Это помогло мне лучше понять особенности татарского национального костюма, их обычаи и традиции. Я пришла к выводу, что в национальном костюме татар воплотилось все мастерство народного творчества и бесконечное стремление этого народа к совершенству. Татарский национальный костюм рассказывает об индивидуальных чертах человека, его характере и эстетических вкусах.

Сейчас, к сожалению, мы не можем увидеть на улице людей, одетых в свои национальные костюмы и в своей работе мне бы хотелось описать особенности костюма, по возможности восстановить некоторые элементы одежды, и сшить коллекцию на этой основе, чтобы в будущем люди не забывали о традициях своих предков. Думаю, что своей цели я добилась.

*Литература:*

1.Абдулатипов Р.Г Мой татарский наряд/Серия «Народы моей России». Библиотека Ассамблеи народов России. Научно-популярное, справочное издание._М.: Классик Стиль, 2005.-С.122-123.

2.Валеев Ф.Т. Сибирские татары: культура и быт. – Казань: Татарское кн. изд-во, 1993. – С.11.

3. Е.В. Обслуживающий труд М., 1981

4. Девушки в красном. Вяткина Н С. Наш дом Татарстан.№3 (035), 2015.-С. 84-86.

5.Егорова Р.И Учись шить М., 1989

1. под слоем лака рисунок древесины не должен теряться;
2. при окрашивании (морении) рисунок древесины не должен уничтожаться- это условие ограничивает глубину тона;
3. отделанная поверхность должна быть однородной, не допускаются потеки и пятна - условие определяет толщину лака;
4. отделка должна быть устойчивой к воздействию света, воды, жиров и не стираться со временем.

## 2.3 Правила техники безопасности при ручной обработки древесины

### До начала работы

1. Наденьте спецодежду (фартук с нарукавниками или халат) и головной убор (берет или косынку). Тщательно подберите волосы и заправьте концы косынке.

2. Проверьте наличие инвентаря (сиденье, щетка-сметка, совок), исправность верстака (зажимные коробки, упор для пиления, зажимные клинья, приспособления для чертежа).

3. Разложите на верстаке инструменты индивидуального пользования в порядке, установленном учителем. Удалите с верстака все лишнее.

### Во время работы

1.Надежно закрепите обрабатываемый материал (древесину) в зажимах верстака.

2. Пользуйтесь только исправным, хорошо налаженным и наточенным инструментом. Используйте инструмент только по назначению.

3. Работайте строгальными инструментами, имеющими исправные рожок (шерхебель, рубанок, фуганок) или вывеску (зензубель, калевка, галтель) и округлую и гладкую заднюю часть колодки. Расщепленные части стругов немедленно заменяйте. Ручки инструментов должны быть удобными для работы.

4. Технологические операции (пиление, долбление, сверление, соединение деталей) выполняйте на верстаке в установленных местах, используя приспособления, упоры,

подкладные доски.

5. Не допускайте захламленности верстака отходами, стружками. Своевременно возвращайте учителю инструменты общего пользования.

6. Не отвлекайтесь во время работы, следите за правильными приемами работы.

7. Применяйте при запиливании направитель для опоры полотна инструмента.

8. Очищайте струги (рубанок, шерхебель, фуганок) от стружек деревянными клиньями.

9. В случае порчи инструмента во время работы немедленно замените его.

**После окончания работы**

1. Проверьте состояние инструментов и в случае неисправности доложите учителю.

2. Приведите в исправное состояние инструменты (снимите заусенцы на молотке, зубиле, кернере, очистите напильники от стружки).

3. Тщательно уберите рабочее место (стружку и опилки не сдувайте и не смахивайте руками). Отходы сложите в специальный ящик.

4. Положите инструменты в порядке, установленном учителем.

5. Приведите себя в порядок.

6. Из мастерской выходите только с разрешения учителя.

**Правила техники безопасности при обработке древесины электроинструментом.**

При работе ручными электроинструментами необходимо убедиться что они заземлены. Начинать и производить работу можно только убедившись в полной исправности электроинструмента и в надежном закреплении режущего инструмента. При включенном электродвигателе запрещается устранять неисправности. При всяком ремонте необходимо отсоединить питающий шнур от сети. Включать электродвигатель следует только перед самым началом рабочей операции. При всяком перерыве в работе двигатель должен быть выключен. Необходимо следить за исправностью изоляции питающего шнура, не допускать его перекручивания. Питающий шнур не рекомендуется прокладывать через подъездные пути и в местах складирования материалов. Если же избежать этого невозможно, шнур необходимо подвешивать или прикрывать досками, чтобы надежно защитить от повреждений. Не разрешается оставлять без надзора электроинструмент, присоединенный к электросети; смену каких-либо частей инструмента нельзя производить при включенном в сеть электродвигателе.

## III. ЗАКЛЮЧЕНИЕ

### 3.1 Время изготовления

Для изготовления журнального столика потребуется 17-20 часов времени.

### 3.2 Экономические расчеты

Чтобы подсчитать затраты на изготовление столика нужно знать стоимость материалов, из которых изготавливаются изделия, затраты на электроэнергию, на амортизацию (износ) оборудования и отчисления на зарплату.

Все детали изделия изготовлены из древесины. Сначала находим объем всего использованного материала. Для этого находим объем каждой детали по формуле: V = axbxs, где V – объем, s – толщина, a – длина, b – ширина. Затем сложив объемы всех деталей вместе находим объем всего использованного материала.

Для изготовления столика я использовал всего $V_1$= 0,0085 $м^3$ доски . Цена 1 $м^3$доски обрезной 4500 рублей , отсюда цена всей использованной доски S = 0.007 Х 4500 = 31.50 рублей. $S_2$=0.058 $м^2$ фанера. Цена с толщиной 10мм - 65.35 рублей.. Цена пиломатериалов составляет 96.85 рублей.

Энергозатраты(мощности электроинструментов умножаем на использованное время) составили 0.4 кВт*час х 2.15 руб.=0.86 руб.

Для сборки изделия использовал 18 саморезов. Цена 1самореза 0.40 рублей. Цена использованных саморезов С = 18 * 0.4 = 7.2 руб.

Для заливки пустот между спилами использовали эпоксидный клей

Цена одного тюбика(280 гр.)-135 рублей. Расход-5 тюбиков:675 рублей.

Для отделки изделия я использовал 250г лака. Цена 1кг лака 220 рублей, отсюда С= 0,25 * 220 = 55 руб.

Общие затраты на изготовление изделия:

С = 96.85 + 0.86+7.2 + 675 + 55= 834.91 руб.

Для изготовления журнального столика потребуется 834.91 рублей.

***3.3 ЭКОНОМИЧЕСКОЕ ОБОСНОВАНИЕ ПРОЕКТА***

Изготовление журнального столика, учитывая только цену использованного материала и энергозатрат обошлось в 834.91 рублей.

С экономической точки зрения это для меня очень выгодно, так как в магазине похожий журнальный столик стоят примерно 2000-2200 руб. Учитывая все это, мою работу можно оценить в 1161 рублей. Если сравнить это цену с себестоимостью изделия то я получаю хорошую выгоду, а эта ощутимая выгода для семейного бюджета.

**3.4 Экологическая оценка проекта**

При изготовлении журнального столика я использовал древесину. Дерево как художественный материал является природным, экологическим чистым сырьем, не оказывающим никакого вредного действия здоровью окружающих.

Мой проект не вносит никаких существенных изменений в окружающую среду.

***3.5 ОЦЕНКА ИЗДЕЛИЯ***

Я остался довольным своей работой. Но в изготовлении изделий есть как положительные, так и отрицательные стороны.

Положительные стороны проекта:

- цель достигнута;
- материалы доступны;
- технология изготовления посильна;
- дизайн изделия соответствует назначению;
- изделие имеет низкую себестоимость.

Отрицательные стороны: -1) производство получилась не безотходным; 2) дороговизна эпоксидного клея.

*Использованная литература:*


1. « Школа и производство» №4, 2014 год, Издательство « Школа – Пресс» 2014.
2. Технология 7 кл., издательство «Вентана- Граф» 2014
3. « САМ» журнал для домашних мастеров. Ю.С. Столяров, Москва 2015
4. «Столярные и токарные работы», издательство «РИПОЛ классик», Москва 2008
5. «Народные промыслы» А.Клиентов, Москва 2014
6. Электронная библиотека по технологии


## ЮЛ ЙӨРҮ ӘЛИФБАСЫ


*Нургаянова Зәлинә,2нче сыйныф укучысы,*

*Фәнни җитәкче: Нургаянова Гөлназ Зиннур кызы*

*Т РКукмара муниципаль районы “Пычак урта мәктәбенең*

*Арпаяз авылы филиалы муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесе”*


Һәр баланың тормыш юлы балалар бакчасыннан , мәктәптән башлана. Монда алган тәрбия кешене гомере буе озатып бара.

Сау-сәламәт кеше гел юлда, хәрәкәттә. Тормыш шуңа көйләнгән. Әмма көйләнгән тормыш уяулык тәлап итә.

Соңгы елларда транспортның күбәеп китүе юл һәлакәтләрен арттырды. Имгәнүчеләр һәм игътибарсызлык корбаннары арасында балаларның күп булуы бигрәк тә аяныч.

Һәлакәтләрнең сәбәпләре дә күп төрле: балаларның игътибарсызлыгы, юл кагыйдәләрен үтәргә теләмәүләре, юлда дөрес йөрмәве, иң гади юл билгеләрен дә белмәүләре.

Бөтен кешенең дә сау-сәламәт булып яшисе килә. Һәркем яшәү өчен көрәшә. Шуңа күрә дә бала чактан ук юл кагыйдәләрен өйрәнүне , юл кагыйдәләренә буйсынуны, аларны үтәүне кертергә кирәк.

Мәктәпкәчә белем бирү учреждениясендә моның буенча эш алып бару, төрле чаралар үткәрү, балаларга юл кагыйдәләрен һәм билгеләрен өйрәтү, төгәл үтәргә күндерү, игътибарлы булырга, иптәшләреңә ярдәм күрсәтә белергә өйрәтү максатыннан эшләнә.

Гади чаралар, дәресләр итеп кенә үткәрмичә, төрле кызыклы методлар куллану балаларның игътибарын тагын да җәлеп итә.

Яраткан әкият геройлары, яраткан язучыларыбыз һәм шагыйрьләребезнең кызыклы геройлары белән булган төрле хәлләр, ялгышларны аңлау, төзәтү балаларның хәтерендә кала һәм юлда дөрес йөрергә, игътибарлы булырга ярдәм итә, өйрәтә.

Проектның актуальлеге. Даими үсә һәм катлаулана барган транспорт мөхите шартларында балаларның тормышын һәм сәламәтлеген саклау, балаларны юл хәрәкәтендә хәвефсез катнашырга әзерләү.

Проектның максаты. Балаларның уй-фикер, хәтер күзаллауларын үстерү; таныпбелүгә кызыксынулар тәрбияләү; иҗади сәләтләрен арттыру, юл йөрү кагыйдәләрен төрле ситуациядә куллана белүләрен үстерү.

Проектның бурычлары.

Өйрәтү.Транспорт йөртүче һәм җәяүле функцияләрен башкару турындагы белемнәр һәм күнекмәләрне системалаштыру; балаларны юл киселешләре, юл тамгалары белән таныштыру.

Үстерү. Игътибар, күзәтүчәнлек, хәрәкәт координациясен формалаштыру, проблемаларны мөстәкыйль рәвештә хәл итү һәм транспорт йөртүче, җәяүле буларак үз гамәлләре белән идарә итү күнекмәләрен формалаштыру.

Тәрбияләү. Урамда, транспортта дисциплиналылык һәм үзеңне тоту культурасын тәрбияләү, укучыларда үз тормышларына карата сакчыл караш булдыру.

Проблема сайлау.

Дөньяда бик күп төрле проблемалар булырга мөмкин. Һәм аларны чишү юллары да була. Иң беренче чиратта әйбәтләп уйлап эш итәргә кирәк.

Менә минем дә алдымда проблема тора. Мин үземә, классташларым белән бергәләп уйнарга, үз кулларым белән ясалган өстәл уены ясарга җыенам. Ул уен матур, сыйфатлы һәм файдалы булып булып чыгар дип уйлыйм.

Фикерләрне ачыклау.

Балаларның гомерен һәм сәламәтлеген саклау - безнең милләтебезнең киләчәген саклау дигән сүз ул. Бу проблема бүгенге көндә бик киеренке хәлдә. Балалар белән булган юл – транспорт һаләкәтләре, авыл җирлегендәге юл билгеләренең булмавы, укучыларның юл билгеләрен практикада куллана белмәүләреннән килеп чыга.

Мин үз эшемнең матур һәм файдалы булып чыгуын, классташларыма юл йөрү тамгаларын өйрәнергә булышуын телим һәм мин тырышачакмын

Проектның төп өлеше

Юл билгеләре тарихы

Беренче машиналар барлыкка килгәнче үк ,1529 елда франция патшасы Франциск I юл хәрәкәтен тәртипкә салу указын гамәлгә кертә. Ул җәяүле һәм атта йөрүчеләргә кагылган. Дөресрәге, урамнарда узуны һәм борылуны рөхсәт итми иде.18 гасыр урталарында беренче пар ярдәмендә йөрүче машиналар күренсә, 19 гасырда инде газ һәм электр ярдәмендә йөрүче машиналар барлыкка килә . Бу машиналар белән бергә беренче юл билгеләре дә барлыкка килә. Мәскәүдә исә беренче юл билгеләре 1933 елда күренә башлый. 1949 елда, Икенче Бөтендөнья сугышы тәмамланганнан соң, Бөтендөнья илләре өчен Бердәм Юл йөрү кагыйдәләре системасы кабул ителә. Сезнең белүегезчә, хәзерге вакытта расланган һәм кабул

ителгән 250 юл йөрү билгесе бар. Билгеләр буталып бетмәсен өчен аларны 7 төркемгә бүлгәннәр.

Проект өчен материал туплау .

Уенның атрибутларын ясау өчен эш кораллары һәм җайланмалары тиешенчә итеп куелган өстәл кирәк.

Эш урынында бары тик хәзер эшләнәсе эш өчен кирәкле кораллар, җайланмалар һәм эшкәртеләсе детальләр генә булырга тиеш. Барлык эш өстәлдә башкарыла, эшкәртү детальләрен күз алдында тоту уИнтернет челтәреннән, мәктәп китапханәсеннән юл тамгалары, аларның төрләре турында укып өстәмә мәгълүмат туплады. Сыйныф сәгатьләрендә юл йөрү кагыйдәләре кичәләре үткәрдек, һәм түбәндәгеәрне белдек.

Бу юл билгеләре бездә генә түгел, чит илләрдә дә кулланыла һәм алар бөтен җирдә бертөрле. Урамнар буйлап трамвайлар йөри, автомобильләр, автобуслар, троллейбуслар чаба башлагач, урамнарны сөйләшергә өйрәтергә кирәк була. Бу юллар телендә дөньядагы барлык илләрнең дә урамнары машина йөртүчеләр һәм җәяүлеләр белән сөйләшә. Кеше укырга өйрәнгәндә, аңа хәрефләр күрсәтәләр. Хәрефләрдән сүзләр, сүзләрдән җөмләләр төзелә. Юллар теленең дә хәрефләре бар. Ул юл билгеләре. Ләкин алардан сүзләр төзеп торасы юк. Бер билге-юл сигналын аңлата. Бу сигналлар зәңгәр һәм кызыл каймалы түгәрәкләр, өчпочмаклар, турыпочмаклар... Алар тикмәгә генә шундый формада, төстә түгел. Һәрберсенең үз мәгънәсе бар. Кайберләре “Сак бул” дип кисәтә, кайберләре “Керү яки хәрәкәт тыела”, “Үтү юлы ябык” дип күрсәтә. Ә кайберләре күрсәтелгән юнәлештә барырга рөхсәт итәләр һәм боралар, ә бер төркем билге кешеләргә хезмәт күрсәтү өчен куелган.

Уен атрибутларын ясау.

Юл йөрү билгеләренең тарихы, килеп чыгышы һәм алар турында мәгълүмат туплаганнан соң, без уен атрибутлары ясарга керештек. Беренче эш итеп юл билеләреннән карточкалар ясап, аларны кистек, скотч белән ябыштырдык. Артларына кечкенә генә липучкалар ябыштырып чыктык. Карточкаларны салыр өчен коробка ясап, тышладык. Уенның төп өлеше өчен ковролиннан нигез ясадык, аның өстенә тамгаларны беркетер өчен икеяклы липучка беркеттек.

Ниһаять, эш тәмамланды. “Юл йөрү Әлифбасы” кысаларында ясалган уен әзер. Уенны берничә төрле вариантта (кушымта №2) уйнарга мөмкин. Уенны уйнау үзем һәм иптәшләр өчен кызыклы, файдалы булсын өчен юл билгеләре турында бер- беребезгә табышмаклар, кыска шигырьләр әзерләдек.

Проектның нәтиҗәлелеген бәяләү.

Укучыларның үзләштерү дәрәҗәсен билгеләү өчен сораулар җыелмасы формасында белем һәм күнекмәләрне билгеләү критерийлары ясалды:

1. Күзаллау формалашу дәрәҗәсе
- транспорт чаралары турында
- урам чатлары төрләре
- җәяүлеләрнең юл арткылы дөрес чыгуы

2. Юл билгеләре турындагы белемнәр
- кисәтү билгеләре
- өстенлеккә ишарә итүче билгеләр
- тыючы билгеләр
- боеручыбилгеләр
- мәгълүмат бирүчебилгеләр
- сервис билгеләр

3. Балаларның үз-үзләрен тоту культуралылыгы
- урамда - транспортта.

Йомгаклау

Менә инде минем уеным әзер. Мин бу уенны зур көч белән ясадым. Уен сыйфатлы, матур килеп чыкты. Миңа бик тә ошады. Без аның белән тәнәфесләрдә иптәшләрем белән уйнаячакбыз. Юл йөрү кагыйдәләре турындагы белемнәребезне камилләштерәчәкбез.

Ясаган уеныбыз иптәшләремә бик ошады. Минем нәни кулларым нинди матур, файдалы уен ясады!

Уңай яклары:

- Эшләү бер дә авыр булмады.
- Әйләнә-тирә дәресендә, буш вакытта уйнар өчен менә дигән материал.
- Юл тамгалары турындагы белемемне тагын да арттырдым, тирәнәйттем.

Тискәре ягы:

- Вакытлар үтү белән кәгазь төсен югалтачак, таушалачак

*Кулланылган әдәбият:*

1. Балаларны юл йөрү куркынычсызлыгы кагыйдәләренә өйрәтү. Ф.Ф.Харисов, Ю.Н. Гобанов. КАЗАН - 2005

2. Волков С. Книга о правилах дорожного движения для младших школьников.

3. Лиходед В.И. Уроки светофора. Стихи для детей. – М.: Просвещение.

4. Основы безопасности жизнедеятельности. 2 класс. Материалы к уроку: Пособие для учителя.- Харьков: Веста: Издательство «Ранок», 2001

5. «Пешеходу-малышу»[Изоматериал]: комплект из 8 открыток, 2006

Р.Ш. Әхмәдиева, С.А. Бикчәнтәева, М.Х. Вәлиева, Е.Е. Воронина, А.Н. Сахапов, Т.Т. Федорова «Кече яшьтшге мәктәп укучыларын юлларда хәвефсез тоту кагыйдәләренә өйрәтү». КАЗАН 2010

6. Тошева Л.И. Основы безопасности дорожного движения: 1-4 классы.-М.: ВАКО 2011. -240 с. (Мастерская учителя)

*Интернет ресурслар:*

Дорожная грамота детям http://zanimatika.narod.ru/OBJ1.htm

Загадки по ПДД http://www.stella.or.kz/razvivayshiezanyatia.html

Викторина по ПДД http://www.stella.or.kz/razvivayshiezanyatia.html

Развивающие занятия http://www.stella.or.kz/razvivayshiezanyatia.html

## ӘБИЕМ САНДЫГЫ

*Нуреева Инзилә, 2 нче сыйныф укучысы*

*Фәнни җитәкче: Мөбәрәкова Гөлнара Рамазан кызы*

*РТ Кукмара районы “Ядегәр урта гомуми белем бирү мәктәбе”*

Татар халкы бик күп тормыш сынаулары үтеп, бүгенге көнгә дә килеп җиткән. Кайчандыр югалуга дучар ителгән милләт туган телен саклап кала алган. Гасырлардан-гасырга, буыннан-буынга, әби-бабайдан әти-әнигә, әти-әнидән балага үзләренең борынгы бәйрәмнәрен, гореф-гадәтләрен, йолаларын югалтмыйча тапшырып килгән, һәм алар, күпмедер дәрәҗәдә үзгәреп, югалып бетә язып, безнең көннәргә дә килеп җиткән.

Татар халкының борынгыдан килгән ел фасылларына бәйле Сабантуйлары, Нәүрүз бәйрәмнәре; ислам диненә бәйле Рамазан һәм Корбан бәйрәмнәре; йолаларга бәйле каз өмәсе, исем кую, туй мәҗлесләрен уздыру, кеше күмү, сөннәткә утырту; аулак өйләр, утырмалар бүгенге көндә дә сакланган.

Мин дә милли бәйрәмнәр белән кызыксынам. Шуңа күрә милли бәйрәмнәр, татар халкының гореф-гадәтләренә багышланган материалларны туплап, лэпбук ясап, шунда җыеп барырга булдым. Иҗади эшемне “Әбием сандыгы” дип атадым. Бу сандыгымда дуслар, әти-әниләр, әби-бабайлар һәм укытучылар өчен кирәкле материаллар тупланачак һәм милли бәйрәмнәр, гореф-гадәтләр турында алга таба да тулыланып барачак.

Актуальлеге: бу эшемнең темасы бик актуаль, чөнки һәр кеше үзенең халкының милли бәйрәмнәрен, культурасын, традицияләрен белергә тиеш.

ӘЗЕРЛЕК ЭТАБЫ

Минем алдыма иҗади проектны сайлау проблемасы килеп басты. Бөтен вариантларны да караганнан соң, материалларны туплау өчен лэпбук ясарга булдым. Карап торышка бу бик җиңел эш кебек тоела, ләкин бик күп вакытны сарыф итә. Шулай ук зәвык таләп итә. Мин барлык фантазиямне һәм иҗатымны күрсәтергә, бөтен кешене гаҗәпләндерергә булдым.

Иҗади проектның максаты итеп борынгыдан килгән милли бәйрәмнәр турында мәгълүмат җыю һәм ул җыелган материалны лэпбук ясап тутыру дип алдым.

Максаттан чыгып, үз алдыма түбәндәге бурычларны сайладым:

- халык традицияләрен күзаллау;
- милли бәйрәмнәрдән Сабантуй, Карга боткасы, Каз өмәсе, Нәүрүз белән танышу;
- эстетик зәвык һәм иҗадилыкны үстерү;
- эш сөючәнлек, пөхтәлек тәрбияләү

Тарихи белешмә

Лэпбук — төрле темаларга багышланган һәм төрле формаларда эшләнгән, информацияне үз эченә рәсемнәр, плакатлар, диаграммалар, графиклар формасында туплаган кисәле һәм тәрәзәле китапчыклар коллекциясе яки портфолио. Лэпбукны кеше үз куллары белән кисеп, ябыштырып, тегеп, бер бербөтен формага китерә. Бу инде фантазиядән тора. Аны төрле төсләр һәм формалар белән ясарга була. Нигез булып катыргы яисә каты кәгазь тора. Ул укучының белемен, иҗади сәләтен үстерү өчен, кругозорын баету өчен җыелма образ булып тора.

Лэпбуклар безнең тормышка әле кптәп түгел генә килеп керделәр. Ә иң мөһиме, ул укучылар өчен бик бай материал булыр тора.

Башлангыч идеяләр. Мин эшкә керешкәнче, интернеттан төрле лепбук формалары карап чыктым. Алар барысы да миңа бик ошады.

Иң яхшы идеяне сайлау. Милли орнаментлар, бизәкләр белән танышу минем күңелемә бик якын. Бигрәк тә милли киемнәр һәм бәйрәмнәрне яратам. Лэпбук ясау минем яшь үзенчәлегемә туры килә. Шуңа күрә яраткан темамны иҗади итеп эшләргә була. Мин моңа әзер. Темам “Әбием сандыгы” булгач, лэпбукны да сандык кебек эшләргә кирәк дигән нәтиҗәгә килдем.

Дизайн спецификация

Лэпбукны ясый башлаганчы күп сорау туа:

5. Ничек итеп ясарга

а) нигез итеп нинди материал алырга;

б) лэпбукны ясау;

в) тышлау технологиясе;

6. Эш кораллары, җайланмалар.

7. Ничек урнаштырырга, күләме, формасы.

ТЕХНОЛОГИК ЭТАП

Технологик карта. Лэпбук ясау технологик карта ярдәмендә ясала. Эш тәртибе түбәндәгечә башкарыла (кушымта 2):

- печенье коробкасын яшел тукыма белән тышлау өчен тукыманы үлчәү, кисү, ябыштыру;
- челтәр лента ябыштыру;
- әзер орнаментлар ябыштыру;
- фоамираннан кисәчекләр, шаблон ярдәмендә түбәтәй, читекләр ясау;
- энием ярдәмендә милли киемнәр тегү;
- интернет чыганаклардан милли бәйрәмнәр, гореф-гадәтләр турында материаллар, фотолар туплау;
- аларны кисәчекләргә урнаштыру;
- әзер материалны лэпбукка тутыру;
- иҗади эшемә карап шатлану.

ЙОМГАКЛАУ ЭТАБЫ.

Лэпбукны ясар өчен чыгым бик күп булмады. Клей, челтәр лента, әзер орнамент, фоамиран, әзер кисәкчекләр сатып алдым. Төрле төстәге тукыма, катыргы коробка үземдә бар иде.

Бу лэпбукны ясау барлыгы, үземнең хезмәтемне исәпләмәгәндә, 335 сумга төшә.

Бу лэпбукны эшләгәндә бернинди дә экологик яктан зыянлы булган материал кулланылмады. Тукыма, кәгазь, катыргы белән без көн саен эшлибез. Фоамираннан әйберләр ясау хәзерге заман кулланылышында.

Экологик яктан фоамираннан ябыштырып ясалган әйберләрнең сәламәтлек өчен бернинди дә зыяны юк, киресенчә, ул кәефне күтәрә, күңелне тынычландыра.

Төрле материаллар белән эшләгән вакытта санитар – гигиеник таләпләрне төгәл үтәргә кирәк. Куркынычсызлык кагыйдәләрен дә тиешенчә белү һәм үтәү мәҗбүри. Шулай ук, эшкә керешкәнче, эш урынын әзерләргә кирәк.

Эшкә үзанализ

Ясалган лэпбук иҗади, вакытны һәм акча ягын күп сарыф итмичә бик матур һәм эчтәлекле килеп чыкты. Бүлмәдә мондый бай эчтәлекле, күп итеп материал туплаган, ә иң мөһиме, дәресләрдә һәм дәрестән тыш чараларда рәхәтләнеп кулланырга була торган лэпбук барлык кешеләрне дә сөендерер.

Мин бу проектның темасын алып дөрес эшләдем дигән нәтиҗә ясадым. Әгәр дә без үз алдыбызга максат итеп матур, эчтәлекле һәм оригиналь әйберләр ясауны куябыз икән, без һичшиксез моңа ирешәяәкбез. Бары тик теләк, тырышлык, фантазия, кызыксыну кирәк. Бу иҗади эшне бер җирдән дә сатып алып булмый. Мин горурланып әйтә алам: "Мин булдырдым!". Үземнең шушы эшләгән эшемнән мин тәм табам. Сокланып карап туя алмыйм. Алга таба да милли бәйрәмнәр, йолалар, халык авыз иҗаты турында материаллар туплаячакмын.

ЙомгаклауБу эшемне башкарганда мин милли бәйрәмнәр, йолалар, халык авыз иҗаты, иҗади проект эшчәнлеге турындагы белемнәремне тагын да баеттым. Күләмле эшне башкарып чыгуда үземне, үземнең көчемне сынадым.


*Кулланылган әдәбият:*

1.Бикбулатова М.З. Чигәргә өйрән.-Казан:Тат.кит.нәшр.,1970.-67б.

2. Исламов Ф.Ф. Мәктәптә халык авыз иҗаты әсәрләрен өйрәтү. Казан -1988

3. Сергеева Н.Г. Тылсымлы энә.-Казан:Тат.кит.нәшр.,2001.-24б.

4. Сергеева Н.Г.Әбиемнең сандыгы.-Казан:Тат.кит.нәшр.,1995.-32.

5. "Сөембикә", "Мәгариф" журналлары

6. Интернет-чыганаклар.


## ТАТАР ХАЛКЫНЫҢ ЙОЛА-БӘЙРӘМЕ-КАРГА БОТКАСЫ


*Рамазанова Чулпан, 4 нче сыйныф укучысы*

*Фәнни җитәкче: Рамазанова Фәйрүзә Гарифҗан кызы*

*МБГБУ "Куныр урта гомуми белем бирү мәктәбе"*


"Хәтердән башка йолалар, тәрбиядән башка рухи хәзинә, рухи хәзинәдән башка шәхес, ә шәхестән башка халык – тарихсыз," - дип әйтелә халык мәкалендә.

Һәр милләт үз җирлегендә барлыкка килгән һәм буыннан-буынга күчә торган гореф-гадәтләрен, кешеләрнең яшәү рәвешләрен, йола-бәйрәмнәрен сакларга омтылган. Тормыш–көнкүрештә билгеле бер йолалар үтәү, гореф-гадәтләрне тоту һәм бәйрәмнәр үткәрү барлык милләтләргә дә хас. Ул әлеге милләт мәдәниятенең мөһим бер өлеше булып исәпләнә. Гореф-гадәтләр борын-борыннан халык тарафыннан үтәлеп килә торган бәйрәмнәрне, йолаларны үз эченә ала.

Халык бәйрәмнәре, йолалары – кешене тормыш тәртипләренә һәм таләпләренә күнектерергә ярдәм итә. Эш шунда ки, ул бәйрәмнәрне халыкның олысы-кечесе бергәләп уздыра. Яшь буын бәйрәмдә катнашу тәртибен кечкенәдән үк өйрәнеп үсә. Һәр кеше, табигый рәвештә, үз-үзен тоту гадәтләрен үзләштерә, милли тәрбия ала. Бу гадәтләр югалмасын өчен без аларны онытмаска, хөрмәт итәргә, белергә тиеш. Аларны белсәк, безнең телебез дә югалмас, сакланыр.Шуңа күрә хәзерге заманда бу бик актуаль проблемаларның берсе дип уйлыйм.

Проект эшенең максаты: балаларны татар халкының йола-бәйрәме – “Карга боткасы” белән тирәнтен таныштыру, аларның халык тормышындагы үзенчәлекле урын алып торуын ачыклау.

Бурычлар. 1.Халкыбызның милли традицияләрен торгызу, саклау максатыннан ел фасыллары белән бәйләнешле йола-бәйрәме – “Карга боткасы” белән балаларны таныштыру.

2. Татар халкының милли бәйрәмнәре, йола-уеннары, гореф-гадәтләре аша балаларның аралашу, коммуникатив осталыгын, сөйләм телен үстерү.

3. Укучыларда уен-бәйрәмнәргә карата кызыксыну уяту.

Проектның төре: танып-белү, иҗади.

Эзләнү эшенең предметы: татар халкының йола-бәйрәме - “Карга боткасы”.

Эзләнү эшенең объекты: татар халык авыз иҗаты, гореф-гадәтләр, йолалар.

Баланың яше: 4 нче сыйныф, 10 яшь.

Проектны башкаруда фәнни җитәкченең роле: балаларның яшь үзенчәлекләрен исәпкә алу, танып-белү процессында укучыларның кызыксыну хисләрен үстерү максатыннан кирәкле шартлар тудыру, эзләнү эшчәнлегенә этәргеч бирү ситуациясе булдыру.

Укучының роле: проектның актив катнашучысы булу, барлыкка килгән проблемаларны чишү, кыенлыкларны җиңеп чыгу юлларын табу.

Проектны тормышка ашыру принциплары:

- системалылык;
- фәнни чыганак белән эшләү, эзләнү, материал туплау;
- яшь үзенчәлекләрен исәпкә алу;
- баланың шәхесен хөрмәтләү;
- бала белән сыйныфта, гаиләдә, әйләнә-тирәдәге өлкәннәр белән үзара аралашу һәм хезмәттәшлек итү эшчәнлеге оештыру.

Проектның тематикасы: әхлак тәрбиясе һәм эстетик белем. Проблема: татар халкының йола бәйрәме - “Карга боткасы” ничек үткәрелгән. Проектның актуальлеге: татар халкының гореф-гадәтләрен, милли бәйрәмнәрен белү кирәк дип уйлыйм. Мин алар белән кызыксынам. Шуңа күрә дә шушы теманы сайладым. Үземнең эшемдә мин йола бәйрәме – “Карга боткасы” на, аны үткәрү тәртибенә тукталып китәргә уйладым. Сыйныфташларымны кызыксындыру өчен, бәйрәм турындагы мәгълүматны лэпбукка тупладым һәм анда җыйган материаллар белән таныштырдым.

Гипотеза. Мин проект эшемнең темасын бүгенге көндә кирәкле дип саныйм. Чөнки әби-бабайлар исән вакытта гына татар халкының йола бәйрәмнәренең безнең җирлектә ничек үткәрелүе турында материал туплап була.

Лэпбуктагы тупланган белемнәремне мин сыйныфтан тыш эшләрдә, әти-әниләр алдында чыгыш ясаганда һәм “Карга боткасы” бәйрәме үткәргән вакытта да куллана алам.

Шулай ук сыйныфташларымны җәйге ял лагеренда үткәргән чараларда, татар халкының авыз иҗатының төре - балалар фольклоры үрнәкләре белән якыннан таныштырганда, миңа лэпбукны методик ярдәмлек итеп куллану мөмкинлеге туа.

Төп өлеш. Буыннардан буыннарга күчерик без, халкыбызның затлы мирасын.

Мин еш кына ап–ак чәчле, ак яулыклы 70 яшьлек әбием белән сөйләшеп утырырга яратам. Алар яшь чакта уздырылган бәйрәмнәр, гореф-гадәтләр, йолалар турында сөйләгәндә әбиемнең ягымлы йөзе тагын да җанлана, күзләре яна башлый, тавышы көрәя. Әйе, күңелле,

бик күңелле итеп яшәгән бит безнең әби – бабайларыбыз. Тырыш хезмәттән соң рәхәтләнеп, чын күңелдән ял итә белгән. Тәртип бозулар да булмаган. Халыкның күңеле саф, чиста булган. Кунак булып килгәннәргә кадер-хөрмәт күрсәткәннәр. Ипи-тоз, якты йөз белән каршы алсалар, шундый ук ягымлылык белән озата да белгәннәр алар.

Уен-көлке, җыр-бию белән шаулап-гөрләп торган Сабантуй, Сөмбелә, Нәүрүз, Карга боткасы, Каз өмәләре үзеңне башкалар алдында сынатмау, кешеләрдә тискәре хисләр тудырмау, матурлыкта, җитезлектә, дуслыкта сынатмау өчен көрәш мәйданына әверелгән. Әбием әрнеп: “Милли бәйрәмнәр онытыла бару сәбәпле, кешеләр бер-берсе белән аралашмыйлар, очрашмыйлар, туган-тумачаларын белмиләр. Ә бит мөкатдәс бәйрәмнәребез авыр фаҗигале елларны җиңелрәк кичерергә ярдәм итте, күңелләребезне җылытты, өметләребезне өзмәскә булышты”, - дип әйтеп куя. Әйе, бәйрәм көннәрендә бергәләшеп, туйганчы җырлашып утыруларның рәхәтлеге әби-бабайлар хәтерендә генә саклана. Безнең бәхеткә авылларыбызда матур итеп сөйләп бирә белгән өлкәннәребез сирәк булса да бар. Алар исән чагында, белгәннәрен язып алып каласы, саклыйсы иде. Минем уйлавымча, хәзерге вакытта күптәннән килгән бәйрәм, йолаларын саклау һәм кабат торгызу эшендә эзлеклелек җитми һәм бу борынгы йолаларыбызны начар белүебездән дә килә. Шушы уйлар миңа, өлкән буын хәтерендә сакланып калган, кайбер йола-бәйрәмнәрне язып алырга этәргеч ясады. Мин үз эшемдә безнең төбәктә “Карга боткасы” бәйрәменең ничек уздырылуын күрсәтергә теләдем. Моның өчен миңа шактый эзләнергә, әби-бабайларны күреп, алар хәтерендә сакланып калган хатирәләрне язып алырга кирәк булды. Әгәр дә минем кечкенә генә эшем төбәгебездәге йола-бәйрәмнәрне торгызу һәм яңарту эшенә өлеш кертсә, мин бик бәхетле булыр идем.

“Карга боткасы” бәйрәменең тарихи тамырлары.

Малмыж өязенең көньягында, Минзәлә өязенең кайбер авылларында бу бәйрәмне Дәрә боткасы дип, Мамадыш өязенең төньяк өлешендәге авылларда Зәрә боткасы дип аталган. Бу терминның мәгънәсе безгә ачык түгел.

Татарлар яшәгән көнчыгыш төбәкләрдә – Алабуга, Минзәлә, һ.б. өязләрдә аны Карга боткасы дип йөрткәннәр. Безнең авылда да бу бәйрәмгә Карга боткасы дип исем биргәннәр.

Борынгы мәҗүси инанулар буенча кешеләр язны җылы яклардан кара каргалар алып килә дип уйлаганнар. Шуңа да карлар эреп, сулар ага башлагач, каргалар килү хөрмәтенә “Карга боткасы” бәйрәме ясаганнар. Бәйрәм көнне авыл балалары, куллары белән канат каккан, кош очкан сыман хәрәкәтләр ясап, урам буйлап йөгереп, халыкны бәйрәмгә чакырганнар.

Татар халык календарендагы иң популяр, иң күңелле язгы бәйрәмнәрнең берсе – “Карга боткасы”:

Карга әйтә: карр, карр,
Туем җитте, бар, бар!
Ярма, күкәй алып бар,
Сөт-маеңны салып бар,
Ипи-чәең салып бар,
Карр, карр, карр!

Кайбер төбәкләрдә Карга боткасына азык-төлекне ат белән җыеп йөргәннәр. Җайдак егетләр, һәр капка төбендә туктап:

Казылык! Ярма! Сөт! Күкәй!
Ит тә бир әле, түтәй! –

дип кычкыра торган булганнар. Шулай авылны урап үткәннән соң, карга булып каркылдап, тавык булып кыткылдап, киенеп-ясанып, табигатьнең иң күркәм җиренә, калку чишмә буена юнәлгәннәр. Зур-зур казаннарда аш, ботка пешергәннәр, йомыркалар буяганнар. Аш-суга оста карчыклар карга боткасын өлгерткәнче, төрле уеннар оештырылган. Ботка пешеп өлгергәч, иң башта ботканы барчасы бергә учлап җиргә сипкәннәр, чишмә суына корбан иткәннәр (җир тук булсын, су иясе тотмасын, яңгыр бирсен).

Бәйрәм бергәләшеп ботка ашау белән тәмамланган. Чөнки аңардан авылның барлык кешеләре дә авыз итәргә тиеш булган. Халыкта Карга боткасы ашагач, кеше ел буена сау-сәламәт була, авырмый дигән ышану яшәгән.

Лэпбук "Татар халкының йола-бәйрәме - Карга боткасы".

Бу проектның төп өлеше - "Татар халкының йола-бәйрәме – Карга боткасы" дигән темага лэпбук ясау.

Лэпбук ул - интерактив тематик папка. Яки кулдан ясалган кесәле, ачыла торган матур китап. Аны беренче тапкыр Америкада кулланганнар. Инглиз теленнән тәрҗемәсе (lap-колени,book-книга, «наколенная книга») җыелма-күрсәтмә һәм таратма материаллар тупланган китап. Лэпбук ясаганда билгеле бер тема нигезендә эшләргә кирәк.

Лэпбук нәрсә өчен кирәк?

- Ул бирелгән теманы яхшырак аңлау һәм истә калдыру өчен кирәк.
- Өйрәнелгән материалны системага салырга, ныгытырга ярдәм итә.
- Лэпбукны ясаганда мәгълүматны тупларга һәм җыярга өйрәнәсең.
- Лэпбуктагы материалларны уку сөйләм телен, фикерләү сәләтен үстерә.
- Эшләү дәверендә күзәтүчәнлек арта, чагыштырырга, анализ ясарга өйрәнелә.

Лэпбук нәрсәдән тора? Җыелма-папка, төрле зурлыктагы кесәләр, китапчыклар һәм мәгълүматлар җыелмасыннан.

Лэпбук ясау өчен кирәкле эш кораллары һәм материаллар:

- җирлек өчен каты яхшы картон;
- кайчы, клей, карандаш;
- акварель буяулар, фломастер;
- төсле һәм самоклейка кәгазьләр, рәсемнәр;
- фантазия.

Иң беренче проек эшенә тотынганчы мин теманы сайлап алдым. Сайланган темага перспектив план төзедем. Интернеттан лэпбук турында мәгълүмат һәм аның төрләре белән танышып, материал тупладым.

"Карга боткасы" бәйрәме үткәрү йолалары турында материал туплаганда миңа мәктәп һәм авыл китапханәчеләре, "Авыл музее" җитәкчесе һәм әби-бабайларым бик ярдәм итте.

Лэпбукны татар өе формасында ясадым. Урта битенә "Карга боткасы" бәйрәме үткәрү йоласы турында туплаган материалларны беркеттем. Аның алдыннан бәйрәмне ничек үткәргәннәре турында кыскача яздым. "Карга малаена ярдәм ит" дигән дидактик уеннар да урнаштырдым.

Лэпбук ике яктан гармун төсле җыела. Ике ягында бизәкле матур тәрәзә. Тәрәзәнең сул ягында "Әби нинди бәйрәмгә әзерләнгән" уены. Укучы уң яктагы тәрәзәгә куелган рәсемгә карап, татар халык ашын дөрес табарга тиеш. Мәсәлән, Карга боткасы (ел фасылы – яз) – чүлмәк белән ботка, Сабантуй (ел фасылы – җәй) – бәлеш, Сөмбелә ( ел фасылы – көз) – кәрҗин белән яшелчә һәм җиләк-җимеш, Нардуган (ел фасылы – кыш) – ит бәлеше.

Беренче биткә "Канатларга күтәреп, сезгә яз алып кайттык" дигән исем куйдым.

Аны кара каргаларга багышладым. Кесәләрдә "Кошларны дөрес билгелә", оригами "Кара каргалар", "Кошлар" исемле кроссворд куйдым.

Икенче битне "Май кирәк, ярма кирәк, Карга туена бар да кирәк" дип исемләдем.

Кесәләргә түбәндәге уеннар урнаштырдым:

- "Дәү әнигә ярдәм итик" уены;
- Кроссворд "Татар халык ашлары";
- "Тәрәзәгә кара" уены.

Өченче бит – "Энҗе чәчтем – энҗе җыям". Бу бүлектә Карга боткасына сый җыйганда әйтелә торган котлаулар һәм чакырулар тупланды. Балалар яратып әйтә торган әйтенүләр, эндәшләр, мавыктыргычлар, көйләм такмаклары һәм такмазалар эзләдем.

Аларны туплаганда безнең җирлектә киң кулланганнарын эзләп, төрле чыганаклардан файдаландым.

Бишенче бит – “Уйнадык, шаярдык, көлдек, корып куйдык зур табын”. Балалар болынга җыелгач, картлар тиз генә учак ягып, зур казан асканнар. Кыз балалар су ташыганнар, малайлар учак тирәсендә бөтерелгәннәр. Балалар ботканың пешеп чыкканын казан янында кулга кашык белән тәлинкә тотып көтеп утырганнан соң, ялыгыбрак китсәләр, уйнап алганнар. Ял вакытында тел көрмәкләндергечләр, тел төзәткеч тизәйткечләр, үртәвечләр, алдавыч әкиятләр, мәкаль һәм әйтемнәр, саналмышлар әйтешкәннәр.

Алтынчы бит - “Әй уйныйбыз, уйныйбыз, уйнап һич тә туймыйбыз”. Ботка ашалганнан соң балалар һәм яшүсмерләр төрле уеннар уйнаганнар. Кечкенәрәк балалар бармак уеннары, калганнар аз хәрәкәтле һәм хәрәкәтле уеннар уйнаганнар. Мин бу бүлеккә хәзерге вакытка кадәр сакланып, безнең авылда яратып уйнала торган татар халкының уеннарын җыйдым. Без аларның күбесен озайтылган көн төркемендә өйрәнеп тә киткән идек.

Җиденче бит – “Күч безнең күңелгә, җыр яме, җир яме!” Соңгы биттә татар халкының җырлы-биюле уеннары һәм җырлары тупланды. Бәйрәмнән соң яшьләр “Наза”, “Чума үрдәк, чума каз” һ.б. уеннарны яратып уйнаганнар. Иң яратып җырлана торган җырлар: “Бөрлегәнем бер генәм”, “Күбәләгем”, “Әпипә” булган.

Бу биткә мин тагын “Карга боткасы” пазлы урнаштырдым.

Йомгаклау.

Проект ахырына көтелгән нәтиҗә.

Тарихи төбәкнең йола-бәйрәмнәрен өйрәнү - энә белән кое казуга тиң. Авылда үткәрелә торган бәйрәмнәрнең язма чыганаклары юк диярлек, чөнки аларны язып баручы булмаган. Бердәнбер чыганак - өлкән яшьтәгеләрнең истәлекләре, буыннан–буынга сөйләнеп килгән хатирәләре. Барлык материалларны туплап, мин туган авылымда үткәрелә торган “Карга боткасы” бәйрәмен үткәрү йоласын өйрәнүгә ирештем дип уйлыйм. Лэпбукта җыелган материаллар:

- әхлаклылык, әдәплелек сыйфатлары тәрбияли;
- балаларны татар телендә дөрес һәм матур итеп аралашырга өйрәтә;
- татар халкының электән килгән бәйрәме – “Карга боткасы” турында күзаллау булдыра;
- татар халык авыз иҗаты белән кызыксыну, аңа карата хөрмәт тәрбияли.

*Кулланылган әдәбият:*

1. К.В.Закирова “Уйный-уйный үсәбез”, Казан, “Мәгариф” нәшрияты, 2005
2. Л.И.Минһаҗева “Балалар фольклоры”, Казан, “Хәтер” нәшрияты, 2009
3. Ф.Г.Юсупов “Балалар бакчасы, Казан, “Раннур” нәшрияты, 2003
4. Р.Ф.Ягъфәров “Татар халык уеннары”, Казан, “Мәгариф” нәшрияты, 2002
5. Р.Ф.Ягъфәров “Балалар фольклоры ”, Казан, “Мәгариф” нәшрияты, 2000

## ЧУАР ТАВЫК КӘРЗИНЕ

*Рахимова Әминә, 1 нче сыйныф укучысы,*
*Фәнни җитәкче: Галиева Зөлфия Васыйл кызы*
*ТР Кукмара районы “Ядегәр урта гомуми белем бирү мәктәбе”*

Минем яраткан шөгылем ул - кулдан төрле эшләнмәләр ясау һәм алар белән үземә якын булган кешеләрне сөендерү. Үз кулларың белән ясалган истәлекле бүләк кешеләргә бик күп сөенеч, яхшы кәеф бүләк итә, фантазияне кузгата. Мин бик иҗади бала һәм мин бу сәнгать белән шөгыльләнергә яратам. Үземнең кулдан эшләнгән “Чуар тавык” кәрзинен сезгә дә күрсәтәсем килә. Безнең иҗади эшебез “Чуар тавык кәрзине” дип аталды.

Теманың актуальлеге. Интернетта утырган вакытта папье – маше технологиясе күзгә чалынды. Бу технология белән кәрзин ясап карарга булдык. Матур да, экономияле, һәрвакытта актуаль дә. Папье – маше технологиясе баланың бармак хәрәкәтләре үсешенә дә ярдәм итә. Әлеге кәрзин балалар өчен куркыныч тудырмый, чөнки ул ватылмаячак, һәм ул экологик чиста материаллардан ясалган. Шуның өстенә әле ул үз кулың белән ясалган. Син аны үзеңә кадерле булган кешеңә бүләк итә аласың. Әгәр дә әлеге эшне сыйфатлы итеп эшләргә өйрәнсәң, ул бик кыйммәтле эш булырга мөмкин, чөнки папье-маше технологиясе белән нәрсә телисең шуны ясарга була. Бу гап-гади шкатулка, маска, чыршы уенчыклары, курчаклар һәм йорт җиһазлары да булырга мөмкин.

Иң әһәмиятлесе – фантазия күрсәтү. Кулдан ясалган эшләнмәләр фабрикада җитештерелгәнгә караганда күпкә кыйммәтлерәк, чөнки алар күбрәк вакыт, сәләт күрсәтүне, тырышлык таләп итәләр. Ә бу эшләнмәләрне башкару өчен бары тик иске газета, клей һәм буяулар гына кирәк.

Без шуннан соң эзләнә башладык, аның тарихы, килеп чыгышы, ясау этаплары, нәрсәләр кирәклеген өйрәндек.

ӘЗЕРЛЕК ЭТАБЫ

Проблемалы ситуация

Безнең алдыбызга иҗади проектны сайлау проблемасы килеп басты. Бөтен вариантларны да караганнан соң, папье – маше технологиясе белән кәрзин ясарга булдык. Карап торышка бу бик җиңел эш кебек тоела, ләкин бик күп вакытны сарыф итә. Шулай ук зәвык таләп итә. Без барлык фантазиябезне һәм иҗатыбызны күрсәтергә, бөтен кешене гаҗәпләндерергә булдык. Якыныңа да менә дигән кирәкле бүләк булачак.

Иҗади проектның максаты: папье – маше технологиясе белән кәрзин ясау өлкәсендә үземнең мөмкинлекләрне камилләштерү

Бурычлары:

- папье – маше тарихын өйрәнергә;
- әлеге подделканы ясау технологиясе белән танышырга;
- папье – маше технологиясе белән бүләккә кәрзин ясарга.

Гипотеза: якын дустыңа чыгымсыз гына истәлекле бүләк ясар өчен.

ТАРИХИ БЕЛЕШМӘ

Папье-машеның туган ягы Кытай. Кытайда шулай ук беренче булып кәгазь барлыкка килгән. Папье-машедан ясалган беренче предметлар Кытайда казу вакытында табылган. Бу бик борынгы Кытай шлемнары һәм хәрби киемнәр булган. Аларга катылык өстәү өчен өстән кат-кат лак белән буяганнннар. Бу предметлар Хань нәселенә кагылган (202 б.э.к. — 220 б. э.).

Ул заманнарда папье-машедан ясалган хәрби киемнәр иң нык, саклагыч корал булып торганнар. Ул аларны ук үтеп керүдән саклаган һәм кылыч белән сугышканда, лаклы киемгә тиеп кылыч шуып китә торган булган. Бу хәрби киемнәр ныклыгы белән беррәттән әле бик җиңел дә һәм сугышчыга сугышта хәрәкәтләнергә дә уңайлы булган.

Папье-маше белән кызыксыну Кытайдан Япониягә һәм Персиягә таралган. Алар бу ысул белән бәйрәмнәргә төрле маскалар ясаганнар. Тора-бара бу техника бөтен илгә таралган.

Европа илләре бу технологиягә зур популярлык күрсәтә башлый. XVII нче гасыр урталарында Францияпапье-маше технологиясе белән эшләү өчен үз җитештерү фабрикасын ача. Алар беренче курчаклар җитештерәләр һәм зур популярлык казаналар. Папье-маше атамасы да француз теленнән алынган. Ул “чәйнәлгән кәгазь” дигәнне аңлата.

Папье-маше зур популярлыкны 1800 нче елда казанган. Россиягә бу технологияне Пётр I алып кайткан һәм бу илдәге кәсеп төрләренең артуына китергән. Ул шулай ук сәнгатьнең төрле предметларын коллекцияләүне модага керткән. Ләкин папье-маше технологиясе белән эшләнмәләр җитештерүне сәнгать дәрәҗәсенә җиткерү бары тик XIX гасырда тормышка ашырыла. Папье-маше технологиясе белән бик күп төрле эшләнмәләр башкарылган: урындыклар, шкатулкалар, уенчыклар, маскалар, подностлар, күзге өчен рамкалар, шулай ук төрле өй җиһазлары.

ПАПЬЕ-МАШЕ ТЕХНОЛОГИЯСЕ

Папье-маше технологиясе белән эшләүнең 3 төрле ысулы бар.

Беренче технология— алдан әзерләнгән өлгегә вак-вак юеш кисәкләрдән торган кәгазьне кат-кат итеп ябыштыралар. Классик техникада берничә катламнан 100 катлам кәгазьгә кадәр крахмалдан ясалган клейстер белән ябыштыралар.

Икенче технология буенча эшләнмә кәгазьдән ясалган куе масса белән эшләнелә. Вак-вак итеп киселгән кәгазьгә кайнар су агызыла һәм бер тәүлек җылы урында саклана. Шуннан соң аны кайнаталар, сыгалар, көпшәкләндерәләр һәм киптерәләр.Барлыкка килгән катнашмага акбур кушып яхшылап болгаталар. Болгаткан вакытта катнашмага клей куша баралар. Катнашма сметана яки сыек камыр рәвешенә килгәнче болгатуны дәвам итәләр. Клей урынына крахмалдан ясалган клейстер кулланыла. Камырны алдан эзерләнгән формага салалар яки аның өстенә катлам итеп сылыйлар һәм ахыргача кипкәнче тоталар. Өченче технология буенча эшләнмә фанер шикелле нык картон белән басым астында сылана. Килеп чыккан эшләнмә грунтлана һәм буяла.

БАШЛАНГЫЧ ИДЕЯЛӘР

Бу эшне ясый башлаганчы, интернеттан папье-маше технологиясе белән ясалган берничә кәрзин эзләп таптык һәм үзебезгә ошаганын сайлап алдык.

ИҢ ЯХШЫ ИДЕЯНЫ САЙЛАУ

Мин әкиятләр укырга бик яратам. Кечкенәдән хайваннарны, кош-кортларны яраткангамы, әкиятләрнең дә шул темага булганын яратам. Бигрәк тә “Чуар тавык” әкиятен яратып укыйм. Шуның өчен дә без укытучым белән кәрзин итеп “Чуар тавык” ясарга килештек.

ДИЗАЙН СПЕЦИФИКАЦИЯ

“Чуар тавык кәрзин”ен ясый башлаганчы эш тәртибен булдырдык:

- папье – маше технологиясен өйрәнергә;
- кирәкле булган материалларны әзерләргә;
- кирәкле булган эш коралларын әзерләргә;
- кайда урнаштырырга, күләме, формасы;
- инструкция буенча кәрзинне ясый башларга.

ПРАКТИК ЭТАП

“Чуар тавык” кәрзине технологик карта (кушымта2) ярдәмендә ясала. Эш тәртибе түбәндәгечә башкарыла: шар кабарту, ак кәгазьне вак-вак кисәкләргә кисү, кәгазьне клей ярдәмендә шарның яртысына бер кат сылау, киптерү, кипкәннән соң, газета битләрен вак-вак кисәкләргә кисү, 100 грамм суык суга крахмалны аз-азлап салып болгату, ут өстенә куеп кайнатып чыгару-клейстер ясау, шарның яртысын клейстер ярдәмендә 10 кат газета ябыштыру, кипкән кәгазь эченнән шарны алу, ясалган форманың кырыйларын тигезләп кисү, газета ярдәмендә тавыкның муенына форма ясау, скотч ярдәмендә гәүдәгә ябыштыру, газетны өчпочмак формасында бөкләп койрык ясау, гәүдәгә скотч ярдәмендә ябыштыру, гәүдәнең формасы зурайсын өчен берничә кат газет сылау, клейстер ярдәмендә тавыкка бер кат газет кисәкләре сылау, киптерү, кипкәч А4 кисәкләрен 5-6 кат сылау, ак катыргыдан ике канат ясау, эссе клей белән сылау, салфетканы турыпочмаклык формасында (8 см 3 см) кисеп алу һәм гармон формасында бөкләп кикриген ясау, муеннарын матурлау, йомырка савытын (кәгазь) суда чылатып җепшек масса барлыкка китерү, тавыкка күләм өстәү өчен җепшек массаны тавыкка сылау, пластмасс пычак ярдәмендә баскалап каурый формасы ясау, тәүлек буе киптерү, акриловый буяулар белән буяп матурлау.

Бу копилканы ясау барлыгы, үземнең хезмәтемне исәпләмәгәндә 169 сумга төшә.

Ясалган “Чуар тавык” кәрзине вакытны һәм акча ягын күп сарыф итмичә матур килеп чыкты. Хәзер бу бүләк белән якын булган кешеләрне сөендереп була.

Без бу проектның темасын алып дөрес эшләдек дигән нәтиҗә ясадык. Үз алдыңа максат куеп,телэгэнеңә ирешер өчен күп көч сарыф итсәң, синең барысы да килеп чыгачак. Син үзеңнең эшләгән эшеңә карап үзең үк сөенеч табачаксың. Бу проектны эшләгәндә тагын

да күбрәк белем тупланыла. Күләмле эшне башкарып чыгуда үзеңне, үзеңнең көчемне сыныйсың.

Бу тема буенча эшләү миңа бик ошады. Мин бик күп кызыклы яңалыклар белдем. Куйган максатыма ирештем - нинди матур “ Чуар тавык” килеп чыкты.

Папье-маше технологиясе бер дә авыр түгел. Ләкин ул бик күп түземлелек һәм пөхтәлек таләп итә. Кәрзинне эшләү өчен берничә көн китте. Чөнки эшләнмәне яхшылап киптерергә кирәк. Ләкин сарыф иткән вакытым бер дә юкка түгел. Чөнки мин нәтиҗәдә үз кулларым белән нинди матур кәрзин ясадым. Озакламый туганымның туган көне. Минем истәлекле бүләгем әзер!

*КУЛЛАНЫЛГАН ӘДӘБИЯТ*

1.Иванова Е.П. Поделки из папье-маше. М.: ООО «Книжный клуб семейного досуга». 2011. 64 с.

2.Издательство: "Дрофа Плюс", 2007 г. Папье-маше

3.“Ручная работа” Курица с золотыми яйцами. Анонс youtude.com

## САМОДЕЛЬНЫЙ ИНКУБАТОР ИЗ ДОСТУПНЫХ МАТЕРИАЛОВ

*Салахов Ильдан Ильнурович, ученик 6 класса*
*Научный руководитель: Салахова Альбина Марсилевна, МБОУ "СОШ №8" Елабужского района Республики Татарстан*

Я очень люблю гостить в деревне. Моя бабушка каждый год, весной покупает маленьких цыплят. И вот после одной из таких поездок я подумал, что если этих цыплят вывести самому без курицы. Этот вопрос меня волновал очень сильно, было интересно, как это сделать… Я уже слышал, что цыплят, гусят и утят можно выводить в инкубаторе. Инкубатор можно купить, но просмотрев, разные сайты продажи инкубаторов я понял, что они мне не по карману. И тогда я решил сделать инкубатор своими руками. Мои родители мое предложение поддержали.

**Актуальность:**

1. В условиях вероятного расширения финансовых кризисов в нашей стране, очень важно рост собственного производства, с минимальной затратой семейного бюджета.
2. Актуальность создания инкубатора состоит в том, что птицы в домашних условиях долго и не всегда могут сесть на гнездо для выведения птенцов.
3. При изготовлении инкубатора мы установили, что наше изобретение является экономически эффективным:

а) по себестоимости инкубатора (см. п.2.3.);

б) для работы мы используем временной датчик, на котором устанавливается время его работы. При такой работе мы значительно экономим электроэнергию.

**Цель работы:** Создать самодельный инкубатор и осуществить инкубацию куриных яиц в домашних условиях.

**Задачи:**

1. Подобрать и изучить литературу по заданной теме.
2. Выявить наиболее благоприятные условия для инкубации яиц.
3. Самостоятельно создать инкубатор в соответствии с существующими требованиями.
4. Создать систему электрообогрева, систему охлаждения, систему увлажнения, систему вентиляции.
5. Подобрать соответствующий материал для создания домашнего инкубатора.
6. Изучить работу инкубатора.

7. Выполнить меры предосторожности и безопасности при эксперименте.
8. Следить за температурным режимом, влажностью и положением яиц.
9. Воспитать в себе чувство ответственности.

**Объект исследования.**

Механизм создания инкубатора из современных подручных материалов в домашних условиях для дальнейшего использования в процессе вывода цыплят.

**Предмет исследования.**

Вывод цыплят в домашних условиях.

**Метод исследования**

Анализ литературных источников, наблюдение, сравнение, обобщение, эксперимент.

**Новизна проекта** состоит в том, что мы попытались использовать современные материалы для изготовления домашнего инкубатора, рассчитали его себестоимость и доказали, что наш инкубатор в 3 раза дешевле промышленного.

**Гипотеза**: если создать инкубатор и необходимые условия в инкубаторе, то возможен вывод цыплят без курицы – наседки.

## 1. Основная часть

### 1.1. Историческая справка об инкубаторах. «Цыплят по осени считают»

Примитивные инкубаторы использовались ещё в давние времена, примерно за полторы тысячи лет до нашей эры. Первое появление инкубаторов зафиксировано в Древнем Египте. Первые инкубаторы представляли собой примитивные устройства - специальные помещения, утеплённые бочки, печи. В то время разведение птицы в инкубаторе было доверено только жрецам, которые имели при храмах достаточно обширные инкубаторы. В некоторых инкубаторах одновременно могло содержаться до нескольких десятков тысяч яиц. Присматривать за инкубаторами приходилось круглосуточно. Следили за внутренней температурой жрецы довольно оригинальным образом. Для этого использовались специальные горшки из глины с жидкостью, которая затвердевала только при определённой температуре. В случае изменения состояния жидкости, температуру поднимали, либо опускали. Для поднятия температуры сжигалась солома, нагревающая довольно толстые стенки. Проходя через стенку, тепло мягко распространялось внутри инкубатора.

Несколько позже, инкубатор был придуман в древнем Китае. Технологии существенно отличались от египетских, и заключались в том, что инкубаторы были расположены в земле. Для этого вырывалась траншея, а на её дно укладывалась мякина. После загрузки яиц, они накрывались внешним слоем мякины, и нагрев происходил с помощью солнечных лучей. Такая система имела серию недостатков, начиная с того, что приходилось подстраиваться к определённым сезонам, и, заканчивая невозможностью определения точной температуры внутри инкубатора. К тому же, инкубатор не имел необходимой вентиляции.

В Европе первый инкубатор изобрел итальянский физик Порт в XVIII веке, когда влияние церкви было чрезвычайно сильно и власти расправлялись со всеми, кто пытался раскрыть тайны природы. Считалось, что такие люди знаются с «нечистой силой» — с дьяволом. Инкубатор Порта был сожжен, но сам изобретатель сумел избежать казни.

В России до революции изготовлением инкубаторов и их применением занимались лишь немногие птицеводы-любители. Обычно инкубаторы выписывались из-за границы. Используемые в то время инкубаторы подразделялись на две группы: с ламповым нагревом и гидроинкубаторы. Инкубаторы первой группы нагревались керосиновыми лампами, где теплоносителем была вода, которая отдавала тепло яйцам. К таким инкубаторам принадлежали аппараты Грюнхальдта, Мартена, Хирсо на и др. В гидроинкубаторах вода не подогревалась в аппарате, а два раза в сутки заменялась кипятком. К таким инкубаторам относились аппараты Арну, Воателье, Венгера и др. Инкубаторы Хирсона, например, изготовлялись различной вместимости — от 12 до 200 яиц. Этот инкубатор в то время был наилучший и пользовался большой популярностью.

Современные промышленные инкубаторы начали развиваться в начале двадцатого века, благодаря чему было положено развитие птицеводства.

### 1.2. Что такое инкубатор

**Инкубатор** (от лат. *incubare*, здесь — высиживаю птенцов) — аппарат для искусственного вывода молодняка сельскохозяйственной птицы из яиц.

Технологический процесс работы такого аппарата основан на равномерном нагреве помещенного продукта. Равномерность нагрева, а также влажность воздуха являются главной составляющей дозревания яиц и их вылупливания. Именно это и определяет основные типы оборудования, которые имеются на современном рынке сельскохозяйственной продукции. Инкубация может совершаться при помощи ручных, механических и автоматических аппаратов.

Песи- йомшак йонлы, зур койрыклы, озын мыеклы йорт хайваны. Алар серле, иркә, матур һәм кызык җан ияләре. Нәкъ менә шуңа күрә дә мин аларны бик яратам. Үземнең дә Йомшаккай исемле бик әйбәт песием бар. Мин аны һәркөн ашатам, аңа сөт эчертәм һәм аның белән уйныйм.

Мин песиләр турында китаплар укырга, мультфильмнар карарга бик яратам. Шуңа күрә песиләр турында күбрәк белергә, өйрәнергә теләгәнлектән, мин үземнең проект эшемнең темасын: "Песи, песи, пескәем"- дип сайлап алдым.

Проектның актуальлеге.

Хәзерге заманда балалар да, өлкәннәр дә күп вакытларын телевизор каршында, компьютер алдында утырып уздыралар. Ә йорт хайваннарына игътибар итәргә вакытлары аз кала. Шуңа күрә бүгенге көндә кешеләрне хайваннар белән аралашырга, аларны кайгыртырга һәм яратырга өйрәтү, кеше тормышында песиләрнең тоткан урынын ачыклау бик мөһим дип уйлыйм.

Проектның максаты.

Песиләр турында күбрәк мәгълүмат алу һәм кеше тормышында аларның тоткан урынын ачыклау.

Бурычлары:

- Песиләр турында мәгълүмат туплау;
- Токымнары белән танышу;
- Песиләр белән бәйле халык авыз иҗаты белән танышу;
- Тупланган материалны бер ситемага салу һәм гомумиләштерү;

Методлар:

- Мәгълүмат туплау;
- Интернет челтәреннән эзләү;
- Күзәтү;
- Әңгәмә;

Объекты: песиләр

1. *Песиләрнең килеп чыгу тарихы .*

Белгечләр фикеренчә, кыргый песиләр якынча 10-12 мең ел элек, кешеләр уртак тормыш алып бара башлау вакытыннан бирле билгеле. Беренче булып аларны Мисырда яшәүчеләр йортка иялэштергән дип тә уйлыйлар. Песиләр өй тирәсендәге тычканнарны юк итәргә булышкан. Шуңа алар тиз арада Азия, Урта Көнчыгыш илләрендә дә тора башлаган.

Россиядә песиләр 11 нче гасырларда барлыкка килгән. Аларны бирегә диңгезчеләр алып кайткан. Һәм бездә яшәүчеләр бу йомшак җанварны бик үз иткән.

2. *Песиләрнең токымнары.*

Дөньяда песиләрнең 200 ләп токымы билгеле. Алар арасында: персид, себер, сиам, британ, свинкс, бенгаль, кимрик, сингапур, чаузи, корат мәчесе дигәннәре һәм башкалар бар. Алар үз эчендә тагын төрләргә бүленә.

Персид мәчеләре, мәсәлән, зур, нык, матур һәм озын йонлы, бик тыныч, ягымлы. Персид мәчеләре бик сирәк тавыш бирә, күп вакыт үзенә игътибар иттерү өчен хуҗасының күзләренә карап тора.

Сиам токымлы песиләр кызыклы тышкы кыяфәте белән аерылып тора: кечкенә баш, бик зур колаклар, зәңгәр күзләр, кыска йонлы кечкенә гәүдә. Сиам мәчеләре ак төсле булып туалар, бер айдан соң борын, колак, аяк һәм койрыклары башка төс ала. Алар нык холыклы булсалар да, үзләренә һәрвакыт игътибар таләп итәләр.

Свинкс мәчеләренең бөтенләй йоны юк, алар озын муенлы, нык гәүдәле, чыбыркы сыман нечкә, озын койрыклы. Шуңа свинкс токымлы песиләре сынны хәтерләтә. Алар шулай ук хәрәкәтчән, җылылык яраталар, хуҗаларнына бик бәйле булалар.

3. *Песиләр белән бәйле халык авыз иҗаты.*

Песиләрнең нинди генә төре булмасын, халык аларны үз иткән, яраткан. Алар белән бәйле күп кенә мәкальләр, табышмаклар, тизәйткечләр, табышмаклар, сынамышлар, юрамышлар, әкиятләр һәм легендалар иҗат иткән.

Мәкальләр:

- *Мәчегә- уен, тычканга- кыен.*
- *Араларыннан кара мәче үткән.*
- *Мәчене түбәдән ыргытсаң да, дүрт аягы өстенә төшәр.*
- *Песинең тычкан сөзәсе юк: мөгез аңа нәрсәгә?*
- *Сыйпаганны песи дә ярата.*
- *Песигә- көлке, тычканга үлем.*

*Табышмаклар:*

- *Нинди аучы, коралсыз,*
  *Җәнлек аулый төн буе?*
  *Аннан, мыегын селкетеп,*
  *Йоклап ята көн буе? (Мәче)*
- *Мыегы бар, сакалы юк,*
  *Туны бар, чапаны юк;*

*Файдасы өйдә булгач,*
*Яланга сәфәре юк.* *(Мәче)*

- *Күзләре ялт-йолт итә,*
  *Мыегы җиргә җитә.*
  *Койрыгы шундый йомшак,*
  *Колаклары өчпочмак.* *(Мәче)*

*Тизәйткеч:*

- *Мич башында биш мәче,*
*Биш мәченең биш башы.*
*Биш мәченең биш башына*
*Ишелмәсен мич ташы.*

Сынамышлар:

- *Песи кыш көне идәнне тырнаса- буран булыр, җәй көне- яңгырга.*
- *Песи юынса, кунак килер.*

Юрамышлар:

- *Мәче кайсы якка карап юына, шул яктан кунак килә.*
- *Кара мәче юлыңны узса, юлың уңмый.*
- *Яңа өйгә- мәче...*

Элек- электән халыкта яңа йортка иң беренче итеп песи керткәннәр. Күпләр кулларына мәче алалар да, үрелеп ишек аша кертеп җибәрәләр, яисә бөтенләй ук кертеп куялар.Бу дөрес түгел. Чөнки өйгә мәче кертүнең мәгънәсе дә шунда: яңа өйгә мәче керерме? Моны белү өчен мәчене ишекнең тышкы ягына, тупса(бусага ) төбенә куялар. Мәче кереп китсә- өйдә шатлык, иминлек булачак, кермичә борылып китсә- өйдә нидер бар, анда ниндидер явыз рухлар кереп өлгергәннәр инде. Мәче керергә теләмәгән өйне “сафландырырга” кирәк, явыз көчне, рухны артыш агачы ярдәмендә куып чыгарырга кирәк. Мәсәлән, өй почмакларыны артыш куаклары элеп калдырырга мөмкин. Кайчакта артыш агачын яндырып, ыслап та алалар. Моннан соң мәчене тагын кертеп карыйлар. Шунысы да мөһим: мәче хуҗаларның үзләренеке булырга тиеш.

Татар халык әкиятләре арасында песиләр турындагы әкиятләр күп түгел дияргә була, шулай да бар. Миңа иң ошаганы-“Мәче белән Аю” әкияте.

*Бер Аю имән башына бал куйган икән. Аны Мәче сизгән дә имән башына менгән. Мәче бал ашап торган чакта, Аю килгән дә:*

*— Монда нишлисең? — дигән.*

*Мәче әйткән:*

*— Менә аюларны, бүреләрне себер җибәрергә язу язамын, мин Мәскәүдән писерь.*

*Аю, бу сүзләрне ишеткәч, артына әйләнеп имән башыннан төшкән дә качкан. Мәче дә, Аюдан куркып, икенче якка йөгергән.*

*Легенда:*

*Ни өчен Эт белән Песи бер-берсенә дошман булганнар?*

*Элекке заманда бер Этне хуҗасы бик начар карый башлаган. Эт, бичара, бик ябыгып, арыкланып, эченнән кылыч күренерлек булып калган, ди. Менә бервакыт аны шул авылның Старостасы күргән дә бик кызганган, аны үз янына чакырып алып әйткән, ди:*

*— Син, төннәр йокламыйча, хуҗаның йортын саклыйсың, көндез аның терлекләрен көтәсең, быелгы ачлыкта, улап-улап, яңгыр китердең. Бар, әйт хуҗаңа, сине, карамыйча, болай ач йөртмәсен; инде ул ашлыгым уңмаган дисә, менә мин синең кулыңа шушы кәгазьне бирәм, яңа ашлык өлгергәч тә, сине ул яхшылап ашатып симертсен, анда да начар ашатса, аңа шушы фәрманны күрсәтерсең! — дип, Староста аңа печать суккан кәгазь тоттырып җибәргән, ди. Эт шул кәгазьне алып киткән, авызында тотып та караган, кулында тотып та караган, кая куярга да белмәгән.*

*— Авызымда йөртсәм чылана, өрсәм, авызымнан төшә, кулымда йөртсәм ертыла, тукта, мин моны Мәчегә биреп саклатыйм, — дигән дә аны чакырып чыгарган. Чыгарган да кәгазен күрсәтеп әйткән, ди:*

*— Мәче дус, менә бу миңа югарыдан төшкән зур кәгазь, минем аны саклар урыным юк, син өйдә торасың, шуңа күрә мин аны сиңа әманәт итеп куеп торам, көз хуҗабыз әвен суккач, мин аны үзем синнән сорап алырмын, син яхшы сакла, — дигән.*

*Мәче кәгазьне «ярый» дип алган да өйгә шома гына кереп киткән. Ләкин Мәчедә Эт кайгысы бармыни? Шул төнне салкын булгач, ул җылыныирга дип, мичкә кереп яткан икән, Этнең боерыгын шунда онытып та калдырган. Иртән торуга мич яксалар, Этнең кәгазе дә шунда янып көл булган, ди.*

*Менә җәй үткән. Яңгырлар явып, игеннәр уңып киткән.*

*Өйдә икмәк тә, аш-су да пешеп тора, ди. Адәмнәр дә тук, Мәче дә тук. Тик хуҗасы бу карт Этне һаман да карамый, ул һаман да ач кала икән. Ник дисәң, аның хуҗасыннан икмәк дәгъва итәргә кулында кәгазе юк. Хыянәтче Мәчедән сора-сорама, хәзер юньләп җавап та бирми, тыр-мыр итә дә, үтә дә китә.*

*Шуннан бирле хәзер Эт, Мәчене күрсә, бердән аңа ташланып:*

*— Ыр-р, ыр-р! Безне ач калдыручылар! — ди икән. Мәче:*

*— Пырых, пырых!.. Без бит тук!.. — дип, йоннарын торгызып, өйгә таба чаба, ди.*

*Һәм шуннан бирле араларында дуслык та беткән, әле дә булса гомер буе ырлы-мырлы, этле-мәчеле булып яшәргә калганнар, ди.*

4.Мәчеләр турындакызыклы мәгълүматлар

- *Иң эре йорт мәчесе - рэгдолл токымлы, аның авырлыгы - 22-25 кг.*
- *Мәчеләрнең иң яхшы сиземләү органы - күзләре.*
- *Мәчеләр шикәр тәмен тоемламый.*
- *Уникенче каттан сикерүче мәченең исән калу мөмкинлеге җиденче каттан сикерүчесенә караганда зуррак.*
- *Канаданың Галифакс шәһәрендә еш кына алты тәпиле мәчеләр туа.*
- *Кара мәчеләр - тыныч, аклары тынгысыз характерлы була.*
- *Песиләр төсләрне таный һәм 60 метр ераклыкта да күрә ала.*
- *Мәче колагында 32 мускул бар.*
- *Песиләр исләрне этләргә ткараганда яхшырак аера.*
- *Песиләр солы, петрушка, шалфей үләннәрен ашый ала, ә әфлисун һәм лимон исен бөтенләй яратмый.*
- *Песиләр тәүлегенә 18 сәгать йоклый.*
- *Алманиядә беренче песиләр музее бар.*
- *1 март- Бөтендөнья Песиләр көне.*

Россиядә песиләр 11 нче гасырларда барлыкка килгән. Һәм шул вакыттан бирле халык песиләрне үз иткән. Алар белән бәйле күп санлы сынамышлар, әйтемнәр, тизәйткечләр, табышмаклар, юрамышлар уйлап тапкан, әкиятләр, легендалар иҗат иткән. Яшәү дәверендә алар турында кызыклы мәгълүматлар да барлыкка килгән. Димәк, кеше тормышында песиләр мөһим урын биләгән.

Бүгенге көндә күп кенә кешеләр өйләрендә песи тота. Алар тычкан тотып кына калмыйлар, кешеләрнең чын дустына әйләнәләр: сырпаланып, күңелне тынычландыралар, балалар белән уйнарга яраталар. Ләкин өйдә песи булган очракта, аларның дөрес туклануын, чиста булуын да карап торырга кирәк.

*Кулланылган әдәбият исемлеге:*

1. Балачак аланы: балалар бакчасы тәрбиячеләре һәм эти- әниләр өчен хрестоматия.-Казан: РИЦ, 2011.Б.- 149.
2. “Салават күпере” журналы.-№3, 2016 нчы ел.
3. Табышмаклар, мәкальләр һәм әйтемнәр, сынамышлар.-Казан: Гыйлем,2014-Б.19,69.
4. Татар халык әкиятләре: Әкиятләр. Казан: Татар. кит. Нәшр, 1989.- Б.60.

Интернет ресурслар:
1. http://sabyem.ru
2. https://yandex.ru/фото

*СЕКЦИЯ «ЮНЫЙ ИССЛЕДОВАТЕЛЬ»*

# БҮГЕНГЕ КӨН БАЛАЛАР ИҖАТЫНДА ЭКОЛОГИЯ ТЕМАСЫ

*Әгълиева Элина, 4 нче сыйныф укучысы*
*Фәнни җитәкче: Гатауллина Лилия Фоат кызы*
*ТР, Кукмара районы, МБГББУ «Кукмара 3-нче номерлы урта мәктәбе»*

*Әй, кеше, уян!*
*Күр! Ишет!*
*Табигать-ананың моң-зарын.*
*Урманын, чишмәсен зарарлый*
*Кешеләр юк итә һәммәсен.*
***Рафыйкова Гүзәл***

Экологик проблема – кешелек дөньясы язмышын билгели торган җитди мәсьәлә. Кешеләр, табигатьне буйсындырып, экологик системаларның тотрыклыгын шактый дәрәҗәдә какшатты. Француз океанологы Жак Ив Кусто моны: «Элек табигать кешене өркетеп торды, хәзер исә кеше табигатьнең үзен куркыта» - дип бәяләде. Аерым илләрдә һәм төбәкләрдә хәл кризис дәрәҗәсенә җитте. Экологик проблема безнең Татарстаныбызны да читләтеп үтми. Ник дигәндә, республикабызда фән һәм техника минут саен үсеп тора, төрле химия, металлургия заводлары көннән-көн арта, кара алтын – нефть чыгару да туктап тормый. Елга-күлләребез пычранды, болын, тугайларыбыз табигыйлыгын югалтты һ.б.

Теманың актуальлеге шунда – берәү дә табигатьтән башка: һава, су, урман-күлләр һ.б. башка яши алмый. Алар безгә һәр мизгел кирәк. Әмма, без табигый байлыклардан фадаланырга гына түгел, аңа ярдәм итәргә дә тиешбез. Соңгы елларда моңа дәүләтебез дә игътибар итә башлады.

Әлеге фәнни эшебездә без экологик мәсьәләләрне хәл итү өчен балалар иҗатыннан җавап эзләргә булдык. Эшебез “Бүгенге көн балалар иҗатында экология темасы” дип атала.

**Максатыбыз** – балалар иҗатында экология темасының бирелешен тикшерү һәм экологик проблемаларны чишү юлларын эзләү.

Максаттан чыгып без үз алдыбызга түбәндәге ***бурычлар***ны куйдык:

1) балалар шигъриятеннән табигатьне саклауга, экологиягә багышланган шигырьләрне туплау;

2) аларда күтәрелгән төп мәсьәләләрне ачыклау;

3) “Экологиябезне саклап калыр өчен ниләр эшләргә кирәк?” дигән анкета уздыру һ.б.

Фәнни-тикшеренү эшенең төп ***объекты*** – балалар шигърияте; ***предметы*** – экологиягә багышланган шигырьләр (126 шигырь).

Әлеге эшне башкарганда түбәндәге ***метод-алымнар*** кулланылды: күзәтү, гомумиләштерү, тикшеренү, эзләнү, анализлау, нәтиҗә ясау.

Фәнни эшне башкарганда Укучылар энциклопедиясе, Рафис Корбан төзегән “Алмаш” китабы, “Вокруг света” журналлары, җирле фактик материаллар һ.б. файдаланылды.

***Бүгенге көн балалар иҗатында экология темасы***

Экология – грек сүзе, «Ойкос» - йорт, ә «логос» - фән дигәнне аңлата, ягъни яшәгән урының, йортың турында фән.

Җир йөзендәге һәр җан иясенең сәламәтлеге, табигатьнең матурлыгы турыдан-туры экологиягә бәйле. Кешеләр гомер-гомердән яшел бишегебез – Җир анабыз үзенең табигый тотрыклыгын мәңге саклар дип уйлаганнар һәм табигатькә үзгәрешләр кертергә *тырышканнар, шуның* белән табигатькә зыян салуларын башларына да китермәгәннәр. Үзен “табигать патшасы” дип исәпләгән адәм баласының эшчәнлеге һәрчак уңай нәтиҗә бирми, киресенчә, фаҗигале үзгәрешләр дә алып килгәли.

Җирнең матурлыгын, һаваның сафлыгын саклау мәсьәләләре яшьләрне дә битараф калдырмый. Аларны кулларына каләм алырга, кешелекне, берничә дустын булса да, үз артыннан ияртеп, Җир анабызның хозурлыкларын саклап калырга өнди. Мондый нәтиҗәгә без яшь каләм тибрәтүчеләрнең иҗатын тикшергәннән соң килдек. Бүгенге көн матбугат битләрендә, мәктәбебез

укучылары иҗатында, Р.Корбан төзегән “Алмаш” китабында урын алган шигырьләрне барладык. Аларның хуҗаларына 8–13 яшь. Аларның әсәрләрен тикшергәннән соң (126 шигырь) түбәндәге нәтиҗәгә юлыктык – әлеге әсәрләрнең 48 % экологиягә: чишмә-сулыкларыбызга, урман-болыннарыбызга, кошларга, хайваннарга һәм аларны саклап калу мәсьәләләренә багышланган (кушымта № 1).

Яшь иҗатчыларның табигатькә, туган ягына багышланган шигырьләре:

Болгар дигән шул авылның
Чылтырап аккан чиста инеше.
Тау битендә кызарып пешкән
Чияләре, җиләк-җимеше.
*Г.Б. Кәлимуллин*

Як-ягыңа карасаң,
Исләрең китә инде.
Болыннары, урманнары
Бигрәк ямьле, сөйкемле.
*А .Гайнанова*

Яратам мин туган авылымның
Күккә ашкан мәгърур тауларын.
Көзләр җиткәч, алтын төскә кергән
Болыннарын, иген кырларын.
*Р.М. Сәхабетдинова*

Балалар табигатьнең һәртөрле матурлыгын күреп шатлана, аның белән горурлана, үзләренең рухи халәтләре дә табигатькә бәйле:

Кояш елмаеп көлде –
Тәрәзәдән өйгә керде.
Агачлар яшелләнде –
Бөтен дөнья ямьләнде.
*А. Җамалетдинова*

Сыерчыкларны күрдеңме,
Яз килә, димәк, тиздән.
Язгы шатлык, кошлар кое
Мәңге китмәс күңелдән.
*Р.Р. Атнагулова*

Шунсын да әйтеп китәргә кирәк, балалар бигрәк тә Җир ананың чишмә-суларына, елга-күлләренә мәдхия укый. Экологиягә багышланган шигырьләр арасында алар 47 % тәшкил итә:

Бар безнең авылда
Саф сулы чишмәләр.
Кешеләр суга дип
Гел шунда төшәләр.
*З.Г. Шәрифуллин.*

Тау астыннан салкын чишмә чыга
Челтерәп ага кумеш сулары
Тирә-ягы куе әрәмәлек
Борма-борма чишмә юллары.
*Ф.И. Хисамов*

Ел фасылларына һәм төрле киек кош, җәнлекләргә, йорт хайваннарына багышланган шигырьләр дә бихисап:

Тәңкә-тәңкә кар ява! –
Мин йөгерәм урамга.
*Г. Фәттахова*

Дүрт аяклы дустым бар,
Исеме аның – Акъяр.
*Р.М. Галиева*

Маэмаемның дүрт көчеге туды,
Шундый матур, шундый нәниләр.
Күзләрен дә әле ачалмыйлар,
Мыш-мыш килеп ята бәбиләр.
*“Маэмаем” Г.Маннапова*

Әтәч киртәгә баскан да
Бар көченә кычкыра.
“Әйдәгез, монда җим күп”, - дип,
Тавыкларын чакыра.
*“Шатлык”, Т.Латыпов*

Балалар табигатьнең матурлыгына дан гына җырлап калмыйлар, ә без – Кешеләрне аны сакларга да чакыралар:

Чишмәләр дә хаклы
Яшәргә омтыла.
Саклыйк без аларны
Киләчәк хакына.
*З.Г. Шәрифуллин*

Әйдәгез, дуслар,
Киттек урманга,
Сыерчыкларга
Оя куярга.
*Ә.Р. Сафина*

6 нчы сыйныф укучысы Зилә Гобәйдуллина үзенең “Саклап калыйк” шигырендә без – кешеләр табигать байлыкларыннан – хуш исле һавасыннан, җиләкле-чәчәкле болыннарыннан һ.б. кулланабыз, ди. Әлеге гүзәллекне киләчәк буынга да тапшырыйк: урман, болын, чишмәләребезне саклыйк, дип чаң кага:

Җир җиләкле болыннарда йөрим,
Хуш исле һавасын сулыймын.

Мондый гүзәллекне, хозурлыкны
Башка бер җирдә дә тоймымын.
Саклап калсак иде бу байлыкны,
Урман, болын, чишмә суларын.
Табигатьнең әрнеп сыкравына
Колак салсын, Җирем, улларың.

*"Саклап калыйк", З.Гобәйдуллина*

Күргәнебезчә, Кеше һәм Табигать арасындагы мөнәсәбәт балалар иҗатында аерым урын тотып тора. Табигать сурәте балалар поэзиясендә гаҗәеп күп төрле функцияләрдә кулланыла, яшъ каләм тибрәтүчеләр иҗатына гуманистик рух, җылы лиризм бөрки. Табигать күренешләре аша дөньяга карашларын, тормыш фәлсәфәсен чагылдыра.

**Йомгаклау**

Йомгаклап шуны әйтергә мөмкин: бүгенге көн балалары экология темасының актуальлеген бик яхшы аңлыйлар. Яшәү йортыбыз булган Җир һәм анда яшәүчеләрнең тормышлары өчен борчылалар. Балалар табигатьнең кешегә яшәү өчен матди мөмкинлекләр дә, иҗат өчен илһам да бирүен дөрес аңлый. Алар җирдәге матурлыкның, табигать –ананың сагында торучы зат - Кеше булырга тиешлекне раслый:

Әйләнә-тирәне саклыйк, Без – табигать баласы! -дип,- әйтәсем килә минем.

Яшүсмер балалар экологиябезне саклау сүздә генә түгел, гамәлдә дә тормышка ашырылуын тели. Моны берничә сыйныфта үткәрелгән сораштыру дәлилли.Укучылар арасында без "Экологиябезне саклап калыр өчен ниләр эшләргә кирәк?" дигән анкета уздырдык. Сораштыру түбәндәге нәтиҗәләрне бирде:

1. Мәктәп программасына Экология фәнен кертергә һәм әлеге фәнне һәр елны укытырга;
2. Даими экологик отрядлар булдырырга;
3. Табигатебезгә зыян салучыларның һәммәсен дә җавапка тартырга;
4. Экологик җинаятьләр өчен штраф күләмен арттырырга;
5. Һәр ел "Чишмә", "Яшел урман", "Экологик сукмак" операцияләре оештырырга;
6. Шулай ук һәр ел агачлар утыртуны булдырырга;
7. Яз, кыш айларында кошларга, хайваннарга ярдәм итүне оештырырга (җимлекләр, оялар ясау, кышкылыкка печән, салам чүмәләләре ясап калдыру һ.б.) һ.б.

Дөрес, бу юнәлештә районыбызның төрле урыннарында, бигрәк тә авыл җирлекләрендә байтак эш башкарыла: районыбызның "Кызыл китабы"н булдыру, ул китапка кертелгән кош-кортларны, үсемлекләрне саклау; елга-чишмәләргә рейдлар ясау, аларны чистарту, яңарту, агачлар утырту, экологик сукмаклар оештыру һ.б. шундыйлардан. Бу мәктәпләрнең алдынгы тәҗрибәсен өйрәнеп, мондый эшләрне республикабызның һәр төбәгендә башкарсак иде.

Безнең бурыч – табигатьне өйрәнү, саклау, үсемлек һәм хайваннар популяциясен арттыруга ирешү.

*Кулланылган әдәбият исемлеге:*

1. Алмаш: Балалар иҗаты / Төзүче, кереш сүз авт. Р.Корбан. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2006. – 159 б.

2. Большая школьная энциклопедия. Гуманитарные науки/ сост. П.Кошель. - М.: ОЛМА-ПРЕСС, 2006. – 446 с.

3. Әдәбиятта экология темасы / Хәлфиева И.А. // Мәгариф № 10 – 2009. - 34-38 бит.

4. Туган як табигате / Билалова Л.А. // Заман сулышы № 34 – 2009. - 3 бит.

5. Энциклопедия школьника / И.А. Михайлова. – М.: Эксмо. 2008. – 512с.:ил.

7. Җирле фактик материаллар.

# СОКТА СОК НИХӘТЛЕ?

*Бикмөхәммәтова Ләйсән, 3 нче сыйныф укучысы*
*Фәнни җитәкче: Газизова Гөлназ Рафаил кызы*
*ТР, Кукмара районы, МБГББУ«Ядегәр авылы урта гомуми белем мәктәбе»*

**Теманың актуальлелеге.** Сок – тәмле һәм кыйммәтле туклану продукты. Сокларда витаминнар, минераль матдәләр һәм углеводлар бар. Соклар организмны ныгыталар һәм тукландыралар, ә бу үз чиратында организмның эшкә сәләтлелеген арттыра. Сокларны регуляр рәвештә куллану организмның матдәләр алмашын яхшырта, инфекцияләргә, стрессларга каршы торучанлыгын арттыра. Ә авырта башласак бер стакан сок безнең оранизмга дару кебек тәэсир итәргә мөмкин. Эш шунда ки, сокларда “уңайлы” молекулалар бар, алар күзәнәк мембранасы аша җиңел үтеп керәләр. Нәкъ менә шуның өчен авырган вакытта һәм авырмаганда да без сокларга мохтаҗ. Иртәнне соктан башлау да бик рәхәт! Бу бик тәмле һәм файдалы. Кибет киштәләре дә сокларның төрлелегеннән сыгылып тора: апельсин, чия, алма, гранат, персик, виноград һәм башка бик күп төрле соклар.

Җитештерүчеләр сокларның бер җимеш яки яшелчәдән торганын, катнаш, витаминлаштырылган һәм гомумән,ниндине телисең шундыйны тәкъдим итәләр. Мондый күптөрлелек балаларның да игътибарын җәлеп итә. Ләкин барлык соклар да файдалымы икән? Сокларның составында нәрсә бар һәм файдалымы бу состав?

**Максат:** Соклар составында ясалма буягычлар, ароматизатор һәм балландыргычлар барлыгын яки юклыгын тикшерү.

**Бурычлар:**

1) башлангыч сыйныф балалары арасында сораштыру үткәрү;
2) өй шартларында сокларны ясалма буягычлар, ароматизатор һәм балландыргычларга тикшерергә өйрәтү;
3) эчемлекләрне дөрес сайларга өйрәтү.

**1.1 Гипотеза**

Кайсы сокларда ясалма буягычлар, ароматизатор һәм балландыргычлар булмавын ачыклап, бу сокларны регуляр куллануга тәкъдим итү.

**1.2 Эзләнү предметы** – сокларда ясалма буягычлар, ароматизатор һәм балландыргычлар булуы

**1.3 Эзләнү-тикшерү объекты** – «Добрый» апельсин согы, “Villa Dini” грейпфрут согы, “Global Villadge” апельсин нектары, “Фруктовый сад” апельсин согы, “Вико” кара карлыган согы, “Гранатовый 555” гранат согы, “Global Villadge” чия согы, үзебез сыккан гранат һәм апельсин согы

**Түбәндәге эзләнү методлары кулланылды:**

- Эксперимент
- Сораштыру

**Сокның барлыкка килү тарихы**

Төрле җимешләрдән ясалган соклар турында беренче язма мәгълүмат борынгы грек язмаларында барлыкка килә. Греклар һәм римлыларның җимеш агачларының җимешләрен көндәлек ашау өчен генә түгел, ә кайбер авыруларга дәва итеп сок рәвешендә әзерләп куюлары да билгеле. Аларда бигрәк тә минераль тозларга (тимер, калий, бакыр), пектинга (0,9%ка кадәр), клетчаткага (4-6%), витамин С га (25мг%), В, В2, РР, фолий кислотасына бай кура җиләге согы популяр булган.

Соклар шулай ук Борынгы Кытай һәм Борынгы Русьта да билгеле әйбер булган. Безнең борынгы бабайларыбыз бигрәк тә облепиханы яратканнар. Себер якларында ул үзенең сыйфатлары аркасында “себер ананасы” дигән исем алган. Облепиха согы витамин җитмәүдән алыштыргысыз чара булып саналган.

Озаграк саклансын өчен яңа сыккан сокны югары темпертура астында эшкәрткәннәр һәм аңарга бал кушканнар.

Совет заманында да төрле җимеш соклары бик популяр булган. Советлар Союзында елына 550 млн.литрлап сок чыгарылган. Күбрәк алма һәм томат нектарлары һәм соклары булган.

1992 елда Россия базарына чит илләрдән картон упаковкаларга тутырылган соклар керә башлый һәм кешеләрнең өстәлләрендә төрледән-төрле диңгез арты җимешләреннән ясалган соклар күренә башлый.

1998 елгы кризистан соң күп кенә чит ил фирмалары Россия базарыннан чыгып киттеләр һәм моның белән үзебезнең җитештерүчеләргә урын бушаттылар.

Бүгенге көндә кибет киштәләрендә чит һәм үзебезнең ил җитештерүчеләре тәкъдим итүче төрледән-төрле соклар бик күп, димәк сайлау мөмкинлеге дә иркен.

**Сокларның классификациясе һәм ассортименты**

Кулланучылар күзлегеннән караганда гадәттә сокларны 3 төргә бүләләр:

1. Яңа гына сыгылган сок – кулланучының янында ук механик рәвештә яки кул көче белән сыгылган сок.
2. Турыдан-туры сыгылган сок – бик яхшы өлгергән җимеш һәм яшелчәләрдән сыгылган, пастеризацияләнгән һәм асептик пакет яки савытларга салынган сок.
3. Тулыландырылган сок – концентрацияле сок белән эчәргә яраклы судан ясалган һәм сатуга асептик пакетларда чыгарылган сок.

Шулай ук соклар түбәндәгечә дә бүленәләр:

| Группа | Сокның төре |
|---|---|
| Җиләк-җимеш соклары | Абрикос, апельсин, виноград, гранат, слива, алма |
| Җиләк соклары | Крыжовник, кара карлыган |
| Яшелчә соклары | Кәбестә, кишер, чөгендер, томат, кабак |
| Агач соклары | Каен, өрәңге |

**Соклар турында кирәкле һәм кызыклы мәгълүмат**

- Сокларны ашказанында югары әчелек, гастрит, колит һәм язва булган кешеләргә кулланырга ярамый. Чөнки сокларда күп булган кислота ашказанының әчелеген тагы да арттыра.
- Яшелчәләрдән ясалган соклар аппетитны баса, димәк мондый эчемлек диета тоткан вакытта файдалы.
- Томат согы рак күзәнәкләренең үсүен туктатырга сәләтле.
- Югары кан басымы белән интегүчеләргә кызыл чөгендер согы эчәргә кирәк. Ул шулай ук организмы шлак һәм токсиннардан да чистарта.
- Апельсин согы иң диетик эчемлек булып санала, ләкин әле ул иң әчесе дә.
- Ананас согы ябыгу өчен иң яхшы эчемлекләрнең берсе булып санала.
- Күп кенә сокларны аерым эчкәнгә караганда бергә кушып куллансак күбрәк файдалырак.
- Тагын бер кызыклы факт. Даруларны сок белән эчеп җибәрергә ярамый. Хәтта грейпфрут согы белән эчү бик куркыныч та – даруның тәэсир итү көче бу сок катнашында бик нык арта.
- Тагын шунысы кызык - “тетрапак” савытларында сатыла торган сокларда чынлыкта сок бик аз була. Ә менә “мультивитаминлы нектар” яратучылар үзләренең саламчык аша җиләк-җимеш һәм яшелчәләрне сыкканнан соң калган өлешен су белән кушып ясалган эчемлек икәнен башларына да китермиләр.

**Тикшеренүләр**

Без төрле фирмаларның берничә төрле сокларын сатып алдык: «Добрый» апельсин согы, “Villa Dini” грейпфрут согы, “Global Villadge” апельсин нектары, “Фруктовый сад” апельсин согы, “Вико” кара карлыган согы, “Гранатовый 555” гранат согы, “Global Villadge” чия согы һәм үзебез гранат һәм апельсин согын сыктык.

«Среда обитания» программасының официаль сайтында без сокларны тикшерүнең төрле ысулларын таптык.

**Сораштыру үткәрү**

Сокларны тикшерергә кирешкәнче без башлангыч сыйныф укучылары арарсында сораштыру үткәрдек. Сораштыруда 30 бала катнашты. Барлык балаларның 21енең (70%) иң яраткан эчемлеге сок булып чыкты. Ачыкланганча иң күп өстенлек бирелүче соклар: алма, апельсин һәм персик согы булып чыкты. Укучыларыбыз фикеренчә, иң тәмле соклар "Добрый" маркасы астында чыгарыла икән: 25 бала (83.3%). "Кайсысы тәмлерәк - үзегез өй шартларында сыккан сокмы яки кибеттән сатып алынган әзер сокмы?" дигән сорауга балаларнның 12се (40%) өй шартларында сыгылган, 14е (46,6%) кибеттән сатып алынган сокларга өстенлек биргән. Ә 4 бала сорауга җавап бирмәгән. Ахыргы сорауга бирелгән җавапларга карасак, сокны көн саен кулланучылар 7 (23,3%), көнаралаш кулланучылар 5 (16,6%), атнага бер кулланучылар 16 (53,3%) укучы булып чыкты.

**Беренче тест – ясалма буягычларга тикшерү**

**а) Кызыл соклар**

Кызыл сокларны (карлыган, чия, җир җиләге һәм виноградны) тикшерү өчен ярты стакан суга 2 чеметем аш содасы өстәргә, болгатырга һәм шушы эремәгә сок өстәргә кирәк. Әгәр дә эчемлекнең төсе үзгәрмәсә, сокта ясалма буягычлар бар. Әгәр сок кызыл-көрән төскә керсә, димәк аны чынлап та җиләк-җимештән сыкканнар.

Кызыл сокларны тикшерү нәтиҗәсе: тикшерелүче 4 сокның берсе – "Гранатовый 555" гранат согында ясалма буягыч барлыгын ачыкландык. Калган соклар сода эремәсе кушкач төсен үзгәртте, димәк аларда ясалма буягычлар юк.

**б) Кызгылт-сары соклар**

Кызгылт-сары сокларны (апельсин, персик, абрикос) икенче төрле тикшерәләр. Сокка сода эремәсе кушалар һәм кайнатып чыгаралар. Әгәр сок шундый ук ачык кызгылт-сары төстә калса, анда ясалма буягычлар бар. Чын табигый сок кайнатканнан соң үтәкүренмәле булып калырга тиеш.

Кызылгылт-сары сокларны тикшерү нәтиҗәсе: тикшерелүче 5 сокның икесендә буягыч матдәләр кушылганлыгын ачыкладык ("Global Villadge" апельсин нектары, "Фруктовый сад" апельсин согы).

**Икенче тест – ароматизаторларга тикшерү**

Күпчелек ясалма ароматизаторларны май нигезендә ясыйлар, шуңа күрә аларны тоеп та белергә мөмкин. Бер тамчы сокны бармаклар арасында ышкып карарга кирәк. Әгәр дә кул майлы шикелле калса, димәк сокка синтетик ароматизатор кушылган.

Тикшерү нәтиҗәсе: барлык сокларның 4сендә ясалма ароматизатор бар: "Фруктовый сад" апельсин согы, "Вико" кара карлыган согы, "Гранатовый 555" гранат согы, "Global Villadge" чия согы.

**Өченче тест – ясалма балландыргычларга тикшерү**

Өй шартларында шулай ук сокка ясалма балландыргыч кушылганлыгын белергә мөмкин. Әгәр эчемлектә табигый шикәр бар икән, аны эчкәннән соң авызда баллылык хисе 5 минут эчендә югала. Ә менә ясалма балландыргыч кушылган булса, бу тоем авызда озак саклана.

Тикшерү нәтиҗәсе: тикшерелүче сокларда баллылык тоемы төрлесендә торлечә саклана, нәтиҗәләрне таблицада күрсәттек.

**Сокларны тикшерүнең җыелма таблицасы**

| Соклар | Ясалма буягычлар | Ароматиза-торлар | Ясалма баллан-дыргычлар |
|---|---|---|---|
| "Добрый" апельсин согы | - | - | 3 мин |
| "Villa Dini" грейпфрут согы | - | - | 1, 5 мин |
| "Global Villadge" апельсин нектары | + | _ | 1 мин |
| "Фруктовый сад" апельсин согы | + | + | 2 мин |
| "Вико" кара карлыган согы | - | + | 4 мин |
| "Гранатовый 555" согы | + | + | 2 мин |
| "Global Villadge" чия согы | - | + | 2 мин |
| Яңа гына сыгылгын гранат согы | - | - | - |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Яңа гына сыгылгын апельсин согы | - | - | - |

**Тикшерү нәтиҗәләре**

Тәкъдим ителгән барлык соклар арасыннан беренче урынны үзебез сыккан апельсин һәм гранат сокларына бирергә булдык, аларның составында бернинди ясалма матдәләр дә юк, файдалы элементлар максималь күләмдә. Икенче урынны “Добрый” апельсин согы һәм “Villa Dini” грейпфрут согы яулады.

Калган соклар үзләренең исемнәрен акламыйлар, чөнки аларга ясалма элементлар кушылган, ә бу организм өчен зыянлы. Закон буенча мондый эчемлекләрне сок дип сатарга ярамый, этикеткада “нектар” яки “эчемлек” дип язарга кирәк.

Әгәр дә сезнең чын табигый сок сатып аласыгыз килә икән, “турыдан-туры сыгылган сок” дип язылган савыттагысын сайлагыз, яки, иң яхшысы, үзегез тиз генә өй шартларында сок сыгып алыгыз.

**Йомгаклау**

Безгә калса, бу тема бик актуаль, чөнки һәрбер сок кулланучы аның сыйфатын белергә тиеш. Сыйфатсыз соклар аллергия реакциясе, ашкайнату системасының бозылуы һәм башка организмга кирәкмәгән тәэсирләр барлыкка китерергә мөмкин.

Фәнни эш төгәлләнгәч түбәндәге нәтиҗәләрне ясадык: әйе, чынлап та, соклар – табигать бүләк иткән, бәяләп бетермәслек хәзинә ул. Иң яхшысы – үзең өй шартларында яңа гына сыккан сок, чөнки әлеге эчемлектә витаминнар, минераллар һәм химик элементлар бик күп була, ә ясалма матдәләр бөтенләй юк. Әгәр дә андый мөмкинлегегез булмыйча, чын табигый сок сатып аласыгыз килә икән, “турыдан туры сыгылган сок” дип язылган савыттагысын сайлагыз.

Сок әле ул организмга файда гына түгел, ә ләззәт алу чыганагы да! Ләкин ләззәт алам дип үзеңнең сәламәтлегеңне куркыныч астына кую дөрес түгел. Шуңа күрә нинди сок эчкәнегезне белеп эчегез, үзегезгә-үзегез игътибарлы булыгыз, үзегезне саклагыз!

*Кулланылган әдәбият:*


1. Амосов И.М., Бендет Я.А. «Здоровье человека», М., 1984г.
2. Петленко В.П. «Валеология человека», Минск, 1996г.
3. Хитров Н.К. «Ваш дом - для вас», М., 1995г.
4. Железняков Ю.В., Назаренко В.М. «Учебно-исследовательские экологические проекты в обучении химии», «Химия в школе», 1999г
5. Кочнев Г.И. «Организация проектно-созидатёльной формы обучения», «Химия в школе», 2000г.


## КӘРӘЗЛЕ ТЕЛЕФОННЫҢ ФАЙДАСЫ ҺӘМ ЗАРАРЫ


*Вәлиева Гөлзия Азат кызы, 3 нче сыйныф укучысы*
*Җитәкче: Яббарова Айгөл Илгизәр кызы*
*ТР, Кукмара районы, МБГББУ«Ядегәр авылы урта гомуми белем мәктәбе»*


21 нче гасыр – яңа технологияләр гасыры. Кесә телефоны мәсьәләсе бүгенге көндә бик актуаль. Бу проблема бигрәк тә укытучыларны, әти - әниләрне борчый. Чөнки күп кенә балалар телефонны иптәше, киңәшчесе, ярдәмчесе дип саный. Алар хәтта урамда кышын чаңгы, чана шууны, җәен балык тотуны шушы иптәшенә алыштыра. Кайберәүләр хәтта күзгә-күз карап сөйләшүгә караганда телефон аша гына аралашуны кулай күрә. Шуңа күрә без кәрәзле телефоннар турында өйрәнеп, аның бала организмына тәэсирен ачыкларга уйладык.

Эзләнү эшенең **максаты**: кәрәзле телефоннарның хәзерге тормышта ролен һәм аның сәламәтлек өчен зыянлы икәнлеген аңлату.

Бу максатны тормышка ашыру өчен түбәндәге **бурычлар** куелды:

- кәрәзле телефоннарның килеп чыгу, аларның камилләшә бару тарихы, төрләре белән танышу;
- кәрәзле телефоннарның файдасын, аларның зарарын ачыклау;
- 2-9 нчы сыйныф укучылары белән анкета үткәрү
- саклану чарасы буларак, кәрәзле телефон белән ничек файдаланырга, аның зарарыннан ничек сакланырга

Бу эшне башкарганда мондый **фаразны (гипотеза)** аерып алдык: Кәрәзле телефоннар файдалымы әллә зыянлымы? Бу фаразны ачыклау өчен иң элек:

-матбугат материаллары ярдәмендә кәрәзле телефоннарның килеп чыгу, аларның камилләшә бару тарихы белән таныштык;

- аларның нинди төрләре белән таныштык,

-безнең мәктәп укучылары белән анкета уздырдык, аның нәтиҗәсен чыгардык,

- борчак бөртекләре белән тәҗрибә ясадык

**Практик әһәмияте:** Бу эшебезнең нәтиҗәсен ачыклагач, кәрәзле телефоннарның зарарыннан саклану чараларын өйрәнеп, буклет эшләп укучыларга тараттык. Бу саклану чаралары барыбызның да сәламәтлеге өчен файдалы булыр дип уйлыйбыз. Эшем буенча презентация ясадык.

**Тикшеренү-эзләнү объекты**: кәрәзле телефон

## I.Төп өлеш

### 1.1. Кәрәзле телфонның килеп чыгу тарихы

Хәзерге заманда телефоннан башка тормышны күз алдына китерүе дә кыен. Без тиз генә бер-беребезнең хәлен белешәбез, өйгә табиб чакыртабыз, телефон ярдәмендә факстан һәм компьютер модемыннан файдаланабыз. Ләкин меңнәрчә еллар кешеләр бер-берсе белән күзгә-күз очрашып кына аралаша алган. Мәсәлән,борынгы кешеләр, үзләрендәге вакыйгалар турында икенче кабиләгә хәбәр итәр өчен, йомычкага шартлы билгеләр язып, аны суга агызганнар. күршеләре, йомычканы алып, хәбәрне “укыган”.

Австралия аборогеннары исә төтен ярдәмендә “сөйләшкәннәр”. Моның өчен төтенне каплап торганнар. Озынрак төтен – бер шартлы билгене, кыскарагы икенчесен белдергән.

Африкада исә барабан кагып хәбәрләшкәннәр.Тау халыклары, аралашу ихтыяҗы туса, бау әйләндергәннәр. Бау очына сыбызгы беркетелгән. Шул сыбызгы җилдә төрле авазлар чыгарган. Шулай итеп, алар үзләренә генә аңлаешлы телдә бик уңайлы хәбәрләшкән.

Ә менә беренче телефонны Америка профессоры, чукрак-телсезләр мәктәбе укытучысы Александр Грехем белл уйлап таба. Беренче телефоннар без хәзер көндәлек кулланган телефоннарга бөтенләй охшамаганнар. Телефонга сөйләүче кеше ишетә, ә тыңлаучы кеше сөйли алмаган.

Беренче телефон станциясе 1882 елда мәскәүдә ачылган. Бу вакытта ул 61 клиентка хезмәт күрсәткән. ә 10 елдан соң аларның саны 1400 гә җиткән.

Хәзерге заманда нинди төр телефоннар булуын ачыклап китик: гади радиотелефон, кәрәзле телефон, рация.

### 1.2. Кәрәзле телефонның зарары һәм файдасы

Соңгы елларда кесә телефоннары тормышыбызга шулкадәр нык үтеп керде ки, ул хәзер әби кулында да, бәби кулында да. Нинди маркадагы һәм нинди бәядәгеләре генә сатылмый кесә телефоннарының. Ә менә зыяны турында уйлап караганыбыз бармы соң?

Кәрәзле телефоннар эш өчен генә файдаланылса, уңайлы әйбер. Ә менә яшүсмерләр кирәксә дә, кирәкмәсә дә тәүлек буенча телефонны куймый. Транспортта, урамда хәтта концерт-спектакльләрдә, мәктәптә дә колагына кесә телефонын куеп сүз куертучыларның күбесе – яшьләр. Укытучылар мәктәп һәм ВУЗларда мобиль куллануны тыю ягында. Калифорния колледжларында бу тыюлар күптән гамәлдә инде.

Белгечләр тикшеренүләре раслаганча, кесә телефоныннан еш файдаланучылар бик күп авыруларга дучар булалар икән. Мәсәлән:

баш авыртуы; баш мие яман шеше; психик авырулар; иммунитет түбәнәю; күз авырулары; нерв авырулары; йөрәк-кан тамырлары авырулары һ.б.

Беренче карашка кәрәзле телефон куллану рәхәт, матур күренеш. Әмма заман яңалыгының балалар өчен генә түгел, өлкәннәр өчен дә зыянлы булуын да онытмыйк әле. Баланың организмы формалашып кына килә, ул үсә. Аның баш сөяге өлкән кешенекенә караганда күпкә нечкәрәк, шуңа күрә баш мие электромагнит нурланышны ун тапкырга артыграк сеңдерә.

Зарары белән беррәттән кәрәзле телефоннарның файдалы яклары да бар. Мәсьәлә: әти-әниләргә шалтыратып була, уйнарга була, интернет, СМС язышып була, GPRS безнең кайда булуыбызны белергә ярдәм итә, музыка тыңлап була, калькулятор, будильник.

**1.3. Кәрәзле телефоннар кирәкме?**

Кесә телефоннарының будильнигы, кинокамерасы, фотоаппараты, SMS, MMS тапшыргычлары, диктофоны, плейеры, калькуляторы бар, вакытны, датаны күрсәтә. Кесә телефонында төрле уеннар уйнап була. Алардан тыш, миникомпьютеры булган смартфоннарда кино карарга, текст белән эшләргә, Интернетка чыгарга мөмкин.

Хәзер инде телефонсыз тормышны күз алдына да китерә алмыйбыз. Ансыз без – «ике кулсыз». Психологлар әйтүенчә, заман кешесе кәрәзле телефон белән дә, ансыз да үзен уңайсыз хис итә. Элемтәсез калсаң, нәкъ шул вакытта бик тә кирәкле кеше шалтыратыр яки әһәмиятле вакыйгадан читтә калырсың кебек.

Моңа кадәр ничек яшәгәнбез икән телефонсыз диючеләр дә аз түгел. Автобуста барабыз, ә үзебез кемнеңдер хәлен сорыйбыз, кемнедер орышабыз, ә кемгәдер аш пешерергә кушабыз… Менә шулай, телефон дигәнең уйларны да, сүзләрне дә секунд эчендә тоташтыра да куя. И – и рәхәт тә соң!

Тик менә укытучының хәлен генә сораучы да, белүче дә юк! Ничек түзә, ничек дәрес алып бара ул бүген! Беркемне кызыксындырмый. Берүзе көрәшә әнә шул кәрәзле телефон белән. Дәрес башлануга әле тегендә, әле монда шалтырый. Укучының игътибары нәрсәгә генә җитсен: дәрес тыңларгамы, җавап бирергәме? Әти – әни телефонның бигрәк акыллысын алып бирә тагын. Уйнап - уены бетми, кирәк икән - фотога төшерә. Дөрестән дә XXI гасыр "могҗизасы" бит бу! Мондый "могҗизалы уенчык"ка үрелмичә бала ничек түзсен?! Аның бөтен уй – фикерен биләп алган ул. Телефон булмаса, нишләр идең дигән сорауга бер укучы: "Аннан башка тормышымны күз алдына да китерә алмыйм", - диде.

Заман алга барган саен тормышыбызга әледән – әле уңайлыклар тудырып, әллә ниләр барлыкка килеп тора. Әмма ләкин әлегә бу дөньяда абсолют файда бирә торган бернәрсә дә юк. Бер рәхәтнең бер михнәте дип, халык тикмәгә генә әйтми. Шуңа күрә һәр нәрсәнең үз вакыты булырга тиешлеген онытмаска, бакча баласына да телефон тоттырмаска иде.

**1.4. Кәрәзле телефонның бала организмына тәэсире**

Кәрәзле телефоннан озак сөйләшү бигрәк тә балалар өчен куркыныч диләр галимнәр. Чөнки кәрәзле телефон чыгарган нурланыш тәэсирендә балаларның иммун системасы җитәрлек үсеш ала алмый. Бигрәк тә баланың баш миенә зур зыян килә. Радиодулкыннар баш мие һәм аның кабыгындагы күзәнәкләрне җимерә, кан әйләнешен авырайта, кан басымын күтәрә һәм кызыл кан тәнчекләре санын киметә. Россиянең баш санитария табибы Геннадий Онищенко: «Кәрәзле телефоннарны балаларга бөтенләй тоттырырга ярамый», - ди. Башка табиблар да балаларның 16 яшькә кадәр телефон кулланмавы яклы.

Телефонга бәйлелек балаларның йокы режимнары бозылуга һәм, моның нәтиҗәсе буларак, иммунитетлары какшауга китерә икән.

**2.5. Кызыклы мәгълүмат**

Лос – Анджелеста яшәүче 29 яшьлек Харриет Хантер исемле кызга телефон җене кагылган. Аның өендә төрледән-төрле 50 телефон, машинасында – 5, ванна бүлмәсендә - 10, караваt янында – 3, гаражында –16, бакчасында – 10 телефон тора икән. Шунысын да әйтергә кирәк, бу аппаратлар барысы да эшли һәм һәрберсе аерым-аерым номерлы. "Миңа аларның шалтыравы ошый, ә инде йөзләгән телефон берьюлы шалтыраса, моннан да зур бәхетнең булуы мөмкин түгел", ди Харриет.

**1.5. Тикшеренүләр**

Безнең авылда кәрәзле телефонның төрле элемтәләре бар: билайн, МТС, мегафон, летай һ.б. Шулай да авылда өлкән кешеләрдә генә кәрәзле телефон юк. Күп гаиләдә һәр гаилә әгъзасының

кәрәзле телефоны бар. 2018 нче елның январь - февраль айларында мәктәпнең 2 – 9 сыйныф укучыларыннан анкета сорауларына җавап алдык. Анкетада барлыгы 58 укучы катнашты.

Анкетада сорауларына җавап алып түбәндәгеләрне ачыкладык: безнең мәктәп укучыларының 43 ендә телефон бар, ә 15 ендә телефон юк. Булганнары арасында иң популяр булган кәрәзле телефон Samsung (11 кешедә), Lenovo (8 кешедә), fly (4 кешедә) һ.б. Укучылар кәрәзле телефоннан иң күбе тәүлеккә1-3 сәг, иң азы 1-3 минут файдаланалар, алар аны күбрәк өйдә калдыралар, кәрәзле телефонны күбрәк интернетта утыру (90%), уен уйнау (40%), сөйләшү (30%) өчен файдаланалар, кәрәзле телефонның кеше организмына тәэсире турында 70% укучы белә, ә 30%ы белми икән әле, ә инде кәрәзле телефонны тыюга 50% риза булса, 50 % каршы.

Шунысын да әйтеп үтәсе килә, безнең укучылар мәктәпкә кәрәзле телефон йөртмиләр, димәк ул дәрескә комачаулык итми.

Кәрәзле телефоннарның зыянын ачыклау өчен без тәҗрибә дә ясадык. Ике бертөрле бер кулланылыштагы савыт алып, аларның икесенә дә бер үк микъдарда борчак бөртекләре салдык һәм бер үк күләмдә, өй температурасындагы су салдык. Стаканның берсен кәрәзле телефон янәшәсенә, икенчесен телефоннан ерак булган урынга һәм икесенә дә яктылык белән җылылык бертөрле килә торган итеп куйдык. Борчак бөртекләренең шытым бирүен көн саен күзәтеп торып мондый нәтиҗәгә килдек: гадәти урында торган борчак яхшы шытым бирде, ә кәрәзле телефон янәшәсендә торган савыт шытымнар аз һәм зәгыйф булды. (Кушымтада фотолары бирелә). Шушы өйрәнүләрдән соң без кәрәзле телефоннар биргән зарардан ничек сакланып булуы турында уйландык, эзләндек һәм моннан саклану чаралары да булуына төшендек. Хәзерге вакытта кәрәзле телефоннар өчен махсус сумка-савытлар сатыла. Аны үзеңә дә тегәргә яки бәйләргә мөмкин.

**III. Нәтиҗә**

Безнең фараз расланды. Хәзерге фән – техниканың бер казанышы булган кәрәзле телефоннарны кулланмыйча яшәү бүгенге көндә мөмкин түгел. Бу әти-әниләргә баласын контрольдә тотарга, кайда нишләвен белеп торырга, кирәк моментта киңәш бирергә ярдәм итсә, өлкәннәргә күп кенә проблемаларны чишү, кайбер мәсьәләләрне ачыклау өчен вакытны экономияләргә булыша. Телефон ярдәмендә интернеттан да файдаланырга мөмкин. Ләкин без телефон алдында корбан булып калырга, аның кулында курчак булырга тиеш түгел...

Кесә телефонының организмга зарарын чикләр өчен Республика медицина профилактика үзәге мондый берничә файдалы киңәш бирә: Кесә телефонын муенда асып йөрмәгез! Әгәр дә экранда “антенналар” аз икән, аны элемтәне яхшы тота торган урынга куярга кирәк. Чөнки элемтәсе начар булган телефонның зарары тагын да күбрәк, җитмәсә батарейкасы да тиз “утыра”. Мөмкин булса, күбрәк өй телефоныннан сөйләшегез.

Ә без кәрәзле телефоннарның зыяныннан саклану чараларын өйрәнгәннән соң, түбәндәгеләрне тәкъдим итәбез:

- Теләсә нинди телефон сатып алганчы, билгеле фирма ясаган телефон алыгыз.
- Сөйләшкәндә телефонны колагыгызгы нык якын китермәгез.
- Телефонны бик кирәк очракларда гына кулланыгыз, бер сөйләшкәндә 3 – 4 минуттан ары сөйләшмәгез. - Кесә телефонын муенда асып йөрмәгез, кесәгезгә дә салмагыз. Аны махсус телефон сумкасына салган хәлдә кул сумкагызда йөртү яхшырак булыр;
- Балаларга һәм үсмерләргә телефон куллану вакытын чикләргә кирәк.

Телефон әхлагы дигәнен дә онытырга ярамый: радиоэлемтә башка кешеләрнең тормышына куркыныч тудырырлык булган очракта телефоныгызны кабызмагыз, спектакль, концерт, кино залларында, музейларда, җыелыш, дәрес барган вакытларда телефоныгызны сүндерегез яки тавышсыз режимга куегыз, транспорт белән идарә иткәндә телефон куллanудан тыелыгыз.

*Кулланылган әдәбият:*


1. Интернет – портал материаллары «REFERAT.RU» ( Бу темага кагылышлы рефератлар, уку һәм мәгълумат материаллары).
2. «Мәгърифәт газетасы» материаллары.
3. «Сабантуй газетасы» материаллары.
4. «Татарстан яшьләре» газетасы материаллары.

5. Физика. Татар гомуми белем бирү мәктәбенең 11 нче сыйныфы өчен дәреслек. Г.Я. Мякишев, Б.Б.Буховцев, В.М.Чаругин. Казан.”Мәгариф” нәшрияты. Москва “Просвещение” 2009.

## ИГРЫ РАЗУМА

*Галиахметов Наиль,ученик 3 класса*
*Научный руководитель: Галиахметова Алсу Салимовна*
*МБОУ “Шеморданский лицей” Сабинского района РТ*

**1.1**. Головоломка — непростая задача, для решения которой, как правило, требуется сообразительность, а не специальные знания высокого уровня.

Тем не менее, некоторые головоломки стимулируют теоретические и практические разработки учёных.

Я решил сделать этот проект именно на тему интеллектуальных игр, так как в последнее время я стал замечать, что почти все ученики нашей школы во время перемен полностью погружены в свои гаджеты.

**1.2. Цель**: этим проектом я хочу «оторвать» детей от телефонов, планшетов и хочу, чтобы они занялись чем-то полезным, то есть головоломками и прочими полезными вещами.

**Задачи**:

1.Изучить головоломки

2.Заинтересовать учащихся головоломкам

3.Научить себя и остальных решать головоломки

**Предмет исследования**: головоломки

**1.3. Гипотеза**: Головоломка – это не просто интересная и увлекательная игра, а еще и возможность саморазвития и самовоспитания.

### Классификация головоломок

**Головоломки с предметами**

Головоломки с предметами – это логические задачи с обычными бытовыми предметами.

***Спички***

Есть огромное количество разных задач связанных со спичками. Одна из них спички вокруг монеты:

Требуется снять все спички, кроме той, которая обращена головкой к монете, соблюдая следующее условие: сначала снять одну спичку, а затем, двигаясь вправо по кругу, снимать каждую тринадцатую спичку.



Какую спичку надо снять первой?

***Три кучки спичек***

На столе лежат три кучки из 11, 7 и 6 спичек. Перекладывая спички из любой кучки в любую другую, нужно сделать так, чтобы в каждой было по 8 спичек. При этом к любой

кучке разрешается добавлять ровно столько спичек, сколько в ней уже есть. Задача решается в три хода.



***Шесть шашек***

Требуется за 9 ходов расставить чёрные шашки слева от белых. При этом за один ход можно передвинуть любую шашку вправо или влево на соседнюю свободную клетку, или перепрыгнуть ею на свободную же клетку через одну или две занятые.




***Перемещение шашек***

На столе в ряд попеременно выложены 6 чёрных и белых шашек:




Требуется переместить шашки так, чтобы слева оказались все чёрные, а справа — все белые. При этом перемещать на свободное место можно только сразу две рядом лежащие шашки, не меняя их порядка.

Для решения задачи достаточно сделать три перемещения.

***Сохранить четность***

16 монет расположены по 4 в ряд: 

Нужно убрать 6 монет так, чтобы в каждом горизонтальном и каждом вертикальном ряду осталось по чётному числу монет.

***Головоломка с 10 монетами***

Расположите в ряд 10 монет. Любую из монет можно перенести над двумя ближайшими к ней и положить сверху на следующую за этими ближайшими. Требуется, следуя этому правилу, переложить монеты так, чтобы они образовали 5 пар, расположенных на равных расстояниях друг



***Квадрат из 16 монет***

16 одинаковых монет расположены в шахматном порядке то верх гербом, то вверх решёткой в виде квадрата:



Как, дотронувшись не более чем до двух монет, перестроить квадрат так, чтобы в каждой горизонтали все четыре монеты были обращены вверх либо только гербами, либо только решёткой?

***7 перевернутых стаканов***

На столе стоят вверх дном 7 стаканов. Разрешается за один раз перевернуть любые 4 стакана. Можно ли через несколько шагов поставить все стаканы в нормальное положение?

***6 стаканов***

На столе стоят 6 стаканов. Первые три пустые, а последние три наполнены водой. Как сделать так, чтобы пустые стаканы и полные чередовались между собой, если касаться можно лишь одного стакана?

**Механические головоломки**

Механическая головоломка — это головоломка, представленная в виде набора механически сцеплённых частей. Самая старая механическая головоломка пришла из Греции.

***Кубик Рубика***

Ку́бик Ру́бика (первоначально был известен как «магический кубик», венг. *bűvös kocka*) — механическая головоломка, изобретённая в 1974 году (и запатентованная в 1975 году) венгерским скульптором и преподавателем архитектуры Эрнё Рубиком.

Считается, что кубик Рубика — лидер среди игрушек по общему количеству продаж: по всему миру было продано порядка 350 млн кубиков Рубика, как оригинальных, так и различных аналогов. Интересный факт: если их поставить в ряд, то они протянутся почти от полюса до полюса Земли.

***Змейка Рубика***

Зме́йка Ру́бика (англ. *Rubik's Snake*) — головоломка, придуманная Эрнё Рубиком, представляющая собой 24 шарнирно соединённых между собой призмы в прямоугольном сечении. Задача состоит в сборке различного рода геометрических фигур, животных и прочих ассоциативных вещей.

Змейка Рубика в развёрнутом виде:

***Пирамидка Мефферта***

Пирамидка Мефферта (англ.*Pyraminx*), «Молдавская пирамидка» или «Японский тетраэдр» — головоломка в форме правильного тетраэдра, подобная кубику Рубика. Каждая грань тетраэдра поделена на 9 правильных треугольников. Задача состоит в том, чтобы перевести пирамидку в конфигурацию с одноцветными гранями. Иногда за схожесть с кубическим аналогом называют также «Тетраэдр Рубика», хотя Эрнё Рубик не имеет никакого отношения к созданию этой головоломки.

Собранная пирамидка:

***Мегаминкс***

Мегаминкс — головоломка в форме двянадцатигранника, похожая на кубик Рубика. Головоломка состоит из 62 видимых снаружи движущихся элементов, 50 из которых меняют

своё местоположение друг относительно друга и 12-ти остальных — центров граней, тогда как в кубике таких перемещаемых частей всего 20 при 6 центрах граней.

Существуют два основных исполнения мегаминкса: шестицветный и двенадцатицветный. В шестицветном исполнении противоположные грани мегаминкса окрашены в один и тот же цвет.

Девятицветный мегаминкс в собранном виде:

Двенадцатицветный мегаминкс, собранный в виде звезды:

В результате этой работы я много узнал о видах логических игр, научился собирать некоторые из них. У меня есть кубики Рубика, у моих друзей есть мегаминксы и пирамидки. Также я выяснил, что нужно срочно популизировать головоломки, так как они развивают память, воображение, конструктивное мышление, умственные способности. Но главное то, что я привлек внимание моих друзей, учителей и других к головоломкам, что очень хорошо.

**4. Список использованной литературы и электронных ресурсов**

1. «Задачи на смекалку» Шарыгин И.Ф., Шевкин А.В., Москва «Просвещение» 2003
2. http://kak-sobrat-kubik-rubika.praya.ru/
3. https://speedcubing.com.ua/
4. http://evrikak.ru/info/kak-sobrat-kybik-rybik-3h3/
5. http://dedfoma.ru/kubikrubika/kak-sobrat-kubik-rubika-3x3x3.htm

## МОЙ ПРАДЕД ЗАЩИЩАЛ РОДИНУ

*Гарифуллина Чулпан, ученица 4 класса*
*Научный руководитель: Гарифуллина Диля Гамилевна*
*МБОУ «Верхнесиметская СОШ» Сабинского района РТ*

*"Не зная прошлого невозможно понять подлинный смысл настоящего и цену будущего."*
*Максим Горький*

Праздник Великой Победы – особенный день, когда решилась история целой страны и история каждого человека. Мы чтим память тех, кто смело ступил на поле боя, кто не опустил лица перед взором смерти, кто прошел, километры боли, чтобы обнять родные плечи. Спасибо героям войны за честь и храбрость!

Наверное, нет ни одной семьи в России, которой не коснулась бы Великая Отечественная война. Кто-то из родных и близких воевал на фронте, другие ковали победу над фашизмом в тылу.

И хотя времени с той поры прошло немало, но живы дети и внуки участников тех страшных военных событий. В их памяти до сих пор скупые рассказы отцов и дедов о том тяжёлом времени для страны и народа.

Данная тема является актуальной по нескольким причинам.

Во-первых, каждый год 9 мая наша страна празднует День Победы, это тот самый день, когда советский народ ценой огромных потерь одержал великую победу над фашистами в годы Великой Отечественной войны.

Во-вторых, к сожалению, всё меньше остаётся в живых ветеранов, поэтому наша задача – собирать, изучать и хранить материал о людях, защищавших нашу Родину.

В-третьих, я считаю, что каждый человек должен знать свою родословную: судьбу своих дедов и прадедов, а затем свои знания передавать будущим поколениям. Для меня очень важно, чтобы осталась память о прадедушке, не только в виде нескольких фотографий и наград, а как целый рассказ, построенный на основе документов и воспоминаний.

**Цель моего исследования:** изучение биографии моего прадедушки – ветерана Великой Отечественной Войны Закирова Мирзаяна Закировича.

**Задачи:**

- изучить семейный архив (фотографии, военный билет, другие документы) времён Великой отечественной войны;
- разыскать информацию об участии моего прадеда в боевых действиях;
- узнать дальнейшую судьбу моего прадеда и его семьи в послевоенные годы.

**Гипотеза:**

Если бы воины не защищали Россию, то, возможно, нас бы не существовало.

**Довоенные годы жизни Закирова М. З.**

Прошло уже 72 года , как закончилась самая страшная трагедия в истории нашей Родины – Великая Отечественная война , но память о ней жива. В каждой семье есть герой , который заслужил вечную память . Такой герой был и в моей семье – мой прадедушка.

Мой прадедушка, Закиров Мирзаян Закирович, родился в 1912 году в городе Мамадыш. Их в семье было четверо родственников. Старший мой прадедушка Мирзаян, братья Раис, Лабиб, сестра Гайша. Но вся его жизнь прошла в городе Елабуге. 11 ноября 1934 года был призван в армию Елабужским военкоматом в 213 ый стрелковый полк. А в 1936 году был уволен в запас

**Боевой путь моего прадеда**. В декабре 1939 года по 16 августа в 1940 года был призван Елабужским военкоматом на финскую войну в 75 автобатальон, был шофером.

В июне 1941 года мой прадедушка и брат Раис были призваны в Великую Отечественную войну. Брат получил контузию и не вылечился, умер. Мой паледушка всю войну служил на северо-западном фронте в составе первой Гвардейской минометной бригады шофёром. По рассказам дедушки он возил боеприпасы на аэродром для летчиков и бойцов.

**Ордена и медали прадедушки**

В 1943 году за боевые заслуги был награжден орденом «Красной звезды».

В 1944 году был тяжело ранен в правую ногу, лежал в госпитале. По состоянию здоровья в августе 1944 года был уволен в запас.

**Послевоенная трудовая деятельность**

После войны мой прадедушка, больной и израненный продолжал полнокровно жить и трудиться. Он работал шофером до пенсии. Мой прадедушка прожил долгую и счастливую жизнь, воспитал четверых детей, дождался внуков. Вдвоём с прабабушкой умели друг друга поддержать, помочь, подбодрить, пошутить. Я считаю, нам многому нужно поучиться у поколения наших «дедов и прадедов»: стойкости, мужеству, воле к Победе, научиться жить так, чтобы не было стыдно перед самим собой. Я не видела своего прадеда, он умер раньше, чем родилась я, но память о нём живёт в сердцах его детей, внуков и правнуков. Мы не имеем права его забыть. Потому что его жизнь – это пример честного служения своему отечеству, народу, нам!

Умер 1984 году 6 апреля в городе Елабуге.

Эти данные о дедушке получила бабушка Рузиля Мирзаяновна в Елабужском военкомате. В настоящее время бабушка находится на заслуженном отдыхе. До пенсии она работала учительницей русского языка и литературы 35 лет в Тимершикской средней школе. В этом году ей исполняется 73 года. Нынче летом бабушка обещала отвезти нас показать дом и места по которым ходил её отец.

**Опрос одноклассников**

Я провела опрос в классе среди одноклассников.

Участие в опросе приняли 8 человек

**Результаты исследования анкет учащихся**

По результатам опроса выяснилось, что все одноклассники знают, когда началась и закончилась Великая отечественная война.

5 ребят указали, что в их семье были родственники, которые участвовали в ВОВ или были тружениками тыла. У 2 ребят не было и один не знает. 3 опрошенных подтвердили, что

в их семьях имеются военные реликвии. Также хочется сказать, что мало кто из них осведомлен о военных реликвиях в их семьях.

Результаты опроса показали, что выбранная мною тема актуальна. Дети нового поколения мало интересуются своими корнями, большинство из них не знают об участниках Великой отечественной войны.

На примере своего прадедушки я показала, что необходимо знать историю своей семьи, так как наши предки были прямыми участниками истории своей страны.

**Выводы**

Занимаясь исследовательской работой, достигая поставленной цели, я увидела, что события Великой Отечественной войны не обошли стороной мою семью. Прадедушка, участник Великой Отечественной войны прошел её достойно. К сожалению, я не смогла восстановить более подробные боевые события моего прадеда. Я сделала вывод о том, что мой прадед является непосредственным участником исторических событий нашей Родины, и история моей семьи перекликается с историей страны.

Сейчас моего прадедушки уже нет, но память о нём навсегда останется в нашей семейной истории и послужит нам примером силы, отваги, мужества , любви к Родине. Я горжусь своим прадедом и благодарна ему!

*Список использованной литературы:*


- книга «Золотые имена» 2004г.
- данные из военкомата г. Елабуги
- интернет страницы
- сайт ОБД «Мемориал»
- семейный архив (фотографии, документы)
- сайт память народ


## БҮЛМӘ ГӨЛЛӘРЕ – ЯШЕЛ ДУСЛАРЫБЫЗ


*Закирова Дәлия Ирек кызы, 2 нче сыйныф укучысы*
*Фәнни җитәкче: Бариева Рәмзия Госман кызы*
*ТР, Теләче районы, МБГББУ - Иске Җөри урта гомум белем бирү мәктәбе филиалы - “Орымширмә башлангыч гомумбелем бирү мәктәбе»*


**Кереш. Бүлмә гөлләренең кеше тормышындагы әһәмияте**

Кешеләр бик борынгы заманнарда ук үзләренең өйләрен матурлау өчен тере үсемлекләр кулланганнар. Башта алар дәвага кулланырга мөмкин булган гөлләрне үстергәннәр. Киселгән, яраланган урыннарны гөл яфраклары белән бәйләп төзәткәннәр. Соңрак өйләрне бизәп торучы матур чәчәкле һәм декоратив яфраклы гөлләрне үстерә башлаганнар.

Кеше һәрдаим табигать белән бәйләнештә яши. Димәк, без үсемлекләр тормышы белән бәйле, дигән сүз. Ә бүлмә гөлләре табигать белән бәйләнешкә керү чарасы. Хәзер инде гөлләр үсмәгән өйне сирәк очратасың. Матур чәчәкле, яфраклы гөлләр кешенең кәефен күтәрә, күңелен тынычландыра. Кышкы салкын көннәрдә гөлләр аеруча күңелгә якын, чөнки бу вакытны табигатьтә бөтен җир ак кар белән капланган була. Алар безне кышын да яшел булулары, ә кайчакта ачык төстәге чәчәкләре белән сокландыра. Гөлләр өйләрне матурлап кына калмыйлар, алар безнең бүлмәләребездәге тузанны йотып саф һавага баеталар, һаваны дымландыралар, зарарлы микроорганизмнарны юк итәләр.

Мин сыйныфтагы гөлләр белән танышу, аларның килеп чыгышын белү һәм аларны үстерү өчен кирәкле шартларны өйрәнү масатыннан тикшеренү алып бардым.

**Тикшеренү объектлары**: сыйныфтагы гөлләр.

Түбәндәге **максатлар** куелды:

1. Сыйныф бүлмәсендәге гөлләргә үсү өчен кирәкле шартларны ачыклау.

Тикшеренү эшенең **бурычлары:**

1. Бүлмә гөлләрен тану һәм исемнәрен белү.
2. Бүлмә гөлләренең файдалы һәм зарарлы якларын билгеләү.
3. Бүлмә гөлләрен тәрбияләргә өйрәнү.

5. **Гипотеза:** бүлмә гөлләре җылы як үсемлекләре һәм аларга үсү өчен шул яклардагы шартлар кирәк, дип уйлыйм.

**1 бүлек. Бүлмә гөлләрен өйрәнү**

**1.1. Сыйныф бүлмәсендәге гөлләрнең исемнәре һәм килеп чыгышлары**

Сыйныф бүлмәсендә күп төрле гөлләр үсә: үрмәле, биек булып үсүче һәм кечкенә гөлләр. Гөлләрнең күптөрлелеге бүлмәнең температурасына бәйле. Һәр бүлмәдә температура бертөрле түгел. Гөлләр арасында үрмәләп үсүче, күләгәне яратучы, кояш нурларын яратучылары бар. Шуңа күрә аларны дөрес итеп урнаштыра белергә кирәк. Шулай ук чәчәк атучы һәм яфрактан гына торучы гөлләр дә бар. Алар үзләренең яшел төсләре белән куандыра. Мин аларның исемнәрен һәм Ватаннарын ачыклау максатыннан күп кенә китаплар карадым һәм интернеттан эзләндем, гөлләрне күзәттем. Шуннан соң мин алар турында күп кенә мәгълүмат тупладым.

Мәктәптә булган гөлләрнең Ватаны - Африка, Америка илләре. Чәчәк атучы гөлләр – амариллис, бальзамин, спатифиллум (татарчасы акканат), эухарис (Амазонская лилия), пеларгония ( татарчасы яран гөл). Яфраклы гөлләрдән – монстера, колеус, алоэ үсә. Үрмәле гөл – традесканция.

Алоэ ның үзенчәлеге – дәвалау үзлегенә ия булуы. Киселгән, үлекләгән урынга алоэның яфрагын куеп бәйләсәң, ул төзәлә. Шулай ук аны ютәлдән дә кулланалар. Шуңа күрә аны һәрбер өйдә үстерәләр.

Монстера киселгән сыман зур яфраклы , чәчәксез гөл. Ул зур булып үсә. Тагын бер үзенчәлеге ачыкланды: аңа кагылсаң, тирене ялкынсындырырга мөмкин.

**1.2. Сорашу үткәрү**

Мин мәктәптә гөлләр турында сорашу үткәрдем. Аның нәтиҗәләре түбәндәгечә булды.

1. Гөлләр кирәкме?




2. Нинди гөлләр яратасыз?




3. Сез гөлләрне тәрбияләргә яратасызмы?



**1.3. Файдалы һәм зарарлы гөлләр.**

Гөлләр турында укыганнан соң, мин кеше тормышына куркыныч янаучы гөлләр турында да белдем. Аларны ике төркемгә бүлдем.

| *Файдалы* | *Зарарлы* |
|---|---|
| Фикус | монстера |
| Алоэ | диффенбахия |
| Спатифиллум | |

**2 бүлек. Бүлмә гөлләренә үсү өчен шартлар**

2.**1. Туфрак**

Бүлмәдә төрле зурлыктагы гөлләр бар. Традесканция, цикламен, пеларгония, алоэ, колеуска уртача зурлыктагы чүлмәкләр кирәк. Ә эунарис, монстера, спаифиллум, амариллис зур булып үсүсче гөлләр, шулай булгач, алар зур

чүлмәкләрдә генә үсә алалар. Гөлләр матур булып үссен өчен, чүлмәккә йомшак, иләнгән туфрак салына.

**2.2. Су сибү**

Бүлмәдә артык эссе булса, гөлләрнең туфраклары тиз кибә. Ул вакытта суны күбрәк сибәсе була. Кыш көннәрендә гөлләргә артык су кирәкми. Ләкин

бальзамин суны ярата, аңа көнаралаш су сибү таләп ителә. Шулай ук чәчәк атучы гөлләр дә суны күп эчә.

**2.3. Яктылык**

Утырткан гөлне кояш төшә торган якты урынга - тәрәзә төбенә куйдык. Гөлләр һәрвакыт кояшка үреләләр. Гел бер якка гына авышып үсмәсен өчен, аны көн саен борып тордым.

Эунарис, алоэ, калеус, амариллис күләгәле урыннарда да үсә ала.

**2.4. Җылылык**

Гөлләргә үсү өчен бүлмә температурасы 15-20 градус җылы булырга тиеш. Термометрдан мин җылылыкны һәр көн күзәтеп тордым. Бальзаминга эссе кояш нурлары кирәкми, ул кояшта шиңә. Пеларгония, декабрист салкынча һаваны да кичерә ала.

**2.5. Чисталык**

Колеус, спатифиллум, эунарис гөлләренең яфракларын йомшак дымлы чүпрәк белән сөртеп, тузаннардан арындырдым. Яфраклары чиста булган гөл яхшы сулый һәм тагын да матур булып күренә.

**Нәтиҗә**

Үткәргән тәҗрибәләр шуны күрсәтә: сыйныф бүлмәләрендә үсүче гөлләр барысы да җылы як үсемлекләре һәм җылы як үсемлекләренә кирәк булган шартлар аларга да кирәк. Декоратив яфраклы гөлләр озак яши, ә чәчәк атучы гөлләр озак яши алмый. Алар үсеп чәчәк атканнан соң, картаялар. Алар урынына яңадан яшь үсенте утыртырга кирәк.

Бүлмә гөлләрен дөрес сайлап алып үстергәндә генә алар кешенең яшел дуслары була ала. Аллергия чыгаручы, чәнчи, тәннәрне зарарлый торган гөлләрне утыртмаска киңәш ителә.

Яхшы туфрак, су, яктылык, җылылык, чисталык булган очракта гына гөлләр үсә ала һәм безне үзләренең матурлыклары белән шатландыра. Чәчәк атучы гөлләр тәрәзә төпләрендә матур күренә. Декоратив яфраклы гөлләр идәнгә, өй почмакларына, өстәл өсләренә куелып, бүлмәләрне тагын да ямьле итә. Гөлләрне иренмичә, күңел биреп тәрбияләгәндә генә матурлыклары белән безнең кәефне күтәрәләр, күңел тынычлыгы бирәләр.

*Кулланылган әдәбият:*

1. В.В.Воронцов, Комнатные растения. Москва, ЗАО «Фитон»1999.

2.Д.Г.Хессайон, Всё о комнатных растениях. Москва, «Кладезь-Букс» 2005.

3. И.И.Рахимов , К.К.Ибрагимова "Растительный и животный мир Татарстана", "Магариф", 2006.

## ВАХИТ БАЗАРЫ ТАРИХЫ

*Кузнецова Кристина Владимировна, 4 сыйныф укучысы*
*Фәнни җитәкче: Шарифуллина Сәлимә Мәхмүт кызы*
*ТР, Мамадыш районы, МБГБУ “Җөри УГБМ”*

Мәгълүматларга күз салсак, соңгы елларда Россиядә авыллар бер-бер артлы юкка чыгып бара. 1989 – 2010 елларда авыллар саны 9,2 меңгә кимегән. Кайбер мәгълүмат чыганакларында көн саен ике авыл юкка чыгуы турында да әйтелә. Шул ук вакытта кешесез авыллар саны да арткannan-арта бара. 1989 елда бу сан 9,4 мең булса, 2010 елда 19,4 меңгә җиткән. 2002 елда алынган мәгълүматлардан республикабызда 3779,3 мең кеше яшәгәне, шуның 988,6 меңе авылларда гомер иткәне билгеле. “Татарстанстат”тан алынган саннарга күз салсак, 2010 елда булган халык санын исәпкә алу барышында республикада 3786,5 мең кеше яшәве ачыкланган. Шуның 932,8 меңе авыл җирләренә туры килә. Татарстанда 2002 – 2010 елларда 8 авыл юкка чыккан. Ә 1920 еллар ахырыннан 2010 елга кадәр меңгә якын авыл, утар юкка чыккан. Татарстанда бүген дә 200ләп авылга юкка чыгу куркынычы яный, аларда 10-20 кеше яши. 2002 елда Татарстандагы 36 авылда кеше яшәмәсә, 2010 елда бу сан 49га җиткән. Соңгы 10 елда Татарстанда авыл халкы 44 меңгә кимегән. Юкка чыккан пунктларның иң күбесен, 20 меңгә якынын авыллар һәм шәһәр тибындагы бистәләр тәшкил итә. Татарстан фәннәр академиясенең Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты галиме Рафаил Шәйдуллин 90 елдан артыграк вакыт эчендә юкка чыккан авыллар саналганнан күбрәк, чөнки беткән авыллар турында бөтен мәгълүмат та сакланмаган ди. Шуңа күрә бүгенге көндә иң актуаль мәсьәләләрнең берсе – авылларны саклап калу мәсьәләсе. Бүген дә мәгарифтә оптимальләштерү сәясәте – балалар аз дип мәктәпләрне ябып кую да аның бетүенә юл ача.

Менә шуларның барысын да искә алып без җитәкчеләрем белән заманында бар яктан да данлыклы, бүгенге көндә бетүгә таба баручы авылларның берсе булган Вахит авылының тирә –якта дан токкан базары турында өйрәнергә булдык. Үткәнен белмәгән халыкның киләчәге юк, шуңа күрә мин авыл тарихын, анда яшәгән кешеләрнең тормыш- көнкүрешләре, нәрсә белән шөгыльләнгәннәрен өйрәнергә булдым. Фәнни – тикшеренү эшенең максаты итеп авыл тарихында халкының горурлыгы булып саналган “Вахит базары”ның эшчәнлеген өйрәнүне куйдым. Максаттан чыгып түбәндәге бурычлар куйдым:

- Базарның килеп чыгу тарихын өйрәнү;
- Вахит авылының горурлыгы булып саналган базарның тарихын өйрәнү;
- Җыелган материалларны анализлау һәм нәтиҗә ясау;
- Фәнни – тикшеренү эшен язу.

Эш барышында мин түбәндәге эзләнү- тикшеренү алымнарын кулландым:

- Тема буенча басылган китаплар һәм башка чыганакларны өйрәнү;
- Мамадыш районы Шәдче авыл җирлегенә кергән авыл кешеләре белән әңгәмәләр уздыру;
- Шәдче, Зур Шыя һәм Җөри урта гомуми белем бирү мәктәпләре, Көек-Ерыкса һәм Шәдче авыл авыл җирлеге архивы һәм интернет чыганаклар белән танышу.

Шулай ук, Р.Газизов редакциясендә “ Мамадышым – язмышым”, Ф.Гарипованың “Авылымны сөям җаным-тәнем белән”, Р.С.Хакимовның “Атлас истории Татарстана и татарского народа” исемле китаплар һәм Мамадыш районы “Нократ” газетасында төрле елларда басылган язмалар файдаланылды.

Фәнни – тикшеренү эшенең объекты төбәгебез авылларының тарихы булса, предметы – Мамадыш районы Вахит авылы.

**Базарның борынгы тарихы**

Ярминкә сүзе борынгы немец сүзеннән барлыкка килеп елга бер була торган сату- алуны аңлата. Урта гасырларда бу сүз байларның үз товарларын елга бер тапкыр даими рәвештә үткәрелә торган сату-алу урынын аңлаткан.

Нәрсә соң ул базар? Борынгы заманнарга әйләнеп кайтсак базар- ул сатучы һәм алучыларның гадәттә периодик рәвештә бергә җыелып сәүдә итүе, шул сәүдә урынына җыелган халык. Икенче мәгънәсе сату-алу мөмкин булган географик өлкә яки хуҗалык тармагы.

Базарның борынгы килеп чыгышына күз салсак без XIV гасырның ахыры, XVI гасырның башына барып тоташырбыз.

Халыкара товар алмашуда әһәмиятле арадашчы буын буларак, Идел Болгары сәүдәне үз кулында тоткан. Аңа аннан файда күп кергән. Шуның өстенә болгар әмире, халыкара килешенгән кагыйдә нигезендә, һәр чит илнең су һәм коры җир кәрванынннан үз дәүләте файдасына товарларының уннан бер өлешен алып калган. Шул ук вакытта, болгар маллары үзләре дә Евразия сәүдә әйләнешендә яхшы бәя тотканнар, аннан да дәүләткә зур файда килгән, илнең экономикасы үскән. Бу сәүдәдә көмеш тәңкәләр әһәмиятле урын тоткан. Башта, алда инде әйтелгәнчә, гарәп дирһәмнәренә охшатып ясалган тәңкәләр, ә соңрак Болгарның үзендә сугылган акчалар әйләнештә йөргән. Бу акчалар Болгар җирләрендә генә түгел, аннан еракта да - Урта Азиядә, Русьта, Балтыйк буе һәм Скандинавия илләрендә табылды.

Акчалы сәүдәдән тыш, Идел Болгары ерак төньяктагы фин-угор халыклары белән турыдан-туры товар алмашып сәүдә иткән. Тагын шуны гына өстисе кала, мондый төр сәүдә шактый озак яшәгән һәм, X - XI йөзләрдәге рәвешеннән әлләни үзгәрмәгән килеш, берничә йөз ел дәвам иткән. Атаклы гарәп сәяхәтчеләре әл-Гарнатый белән Ибне Баттута болгарларда үзләре булып һәм аларның төньяк кабиләләре белән мөнәсәбәтләре турында күп тапкырлар ишетеп, XII һәм XIV йөзләрдә дә шул ук алмашлы сәүдә алымының яшәве турында язып калдырганнар. Әл-Гарнатыйның болгарлар үз товарларына, мәсәлән, диңгез балыклары тоту өчен эшләгән гарпуннар һәм кайбер башка тимер әйберләренә алмашка төньяк кешеләреннән «кеш тиресе алып кайтып гаять күп табыш җыялар» дигән сүзләре бу сәүдәнең файдалы булуын раслый. Болгарлар, төрле сәбәпләр табып, Көнчыгыш сәүдәгәрләрен төньякка үткәрмичә, йөз еллар буена шул табышлы сәүдәне үз кулларында юкка гына тотмаганнар, билгеле.

Каспий диңгезеннән ерак түгел, Җаек елгасының түбән агымында Сарайчык дигән атаклы каланың булганлыгы билгеле. Бүтән калалар шикелле, Сарайчык та зур сәүдә үзәге булган, анда да акча сугылган. Шәһәрнең калдыклары Җаек элеккеге юлына төшкәннән соң су астында калса да, Хәрәземнән Сарайга килүче һәм аннан Кырымга баручы кәрваннарны уздырган бу сәүдә юлы өстендә 15 кәрвансарай билгеле - аларны археологлар казып чыгарды: һәркайсының үз коесы да, ихатасы да, бина эчендә сәүдәгәрләр ял итү өчен бүлмәләре дә була.

Тарихка күз салсак әнә нинди ерак чорлардан килә икән сату- алу белән шөгыльләнү. Вахит авылы халкы да сату-алу белән элек-электән шөгыльләнгән. Тикшерү эше барышында авылның иң өлкән кешеләре белән әңгәмә кору да бу соравыбызны җавапсыз калдырды.

**Вахит базары турында истәлекләр**

Авыл халкы шушы җирдә игенчелек һәм терлекчелек белән шөгыльләнеп, ялгыз хуҗалыклар булып яшәгәннәр. Авылның сабан, арыш һәм парга калдырыла торган басулары булып өч басуда да авылга якын булган урта рәт җирләре хуҗалыкларга даими беркетелгән булган һәм ул җирләргә ашлама- тирес чыгарганнар. Калган урыннардагы җирләр туфрак составларына карап аерым участокларга бүленгән. Хуҗалыклар арасында бу җирләрдән файдалануда ризасызлык чыкмасын өчен ул участокларны җирәбә сикертеп бүлә торган булганнар.

Бу төрле участоклар барлык басуларда да булган. Мәсәлән: зират ягы басуда Аю аланы, Файхрус төплеге, Мулла чирәме, Печәнлеккә башлаш, урта басуда Озын уймак, Торна тавы, Исхак үлгән Янган җир, Чирмеш буе, Акман юлы, Казенный, Яңа янган чыршылык ягы басуда Ташлы елга, Пошай үзәне, Аркылы юл буе, Чишмә өсте һәм Баткаклык.

Авылда хуҗалыкларның күпчелеге экономик яктан ярлы хәлдә яшәгән.Укый-яза белүче кешеләр саны да аз була. Хатын-кызларның гражданлык хокуклары булмау сәбәпле аларга имана җирләре бирелмәгән. Күп кыз балалары булган гаиләләргә тормыш алып баруы бик авыр булган. Күпчелек хуҗалыкларның үз иманаларын сөрер өчен атлары булмау сәбәпле, җирләрен атлы хуҗалыклар, алынасы уңышның яртысы хисабына, эшләп бирә торган булган.

Игенчелек эшләре бик гади кораллар: агач сукалар һәм тырмалар ярдәмендә башкарылган. Чәчүлек җирләре эшкәрткәндә агрономия кагыйдәләре кулланылмаган диярлек, җиргә ашламалар бик

аз күләмдә генә кертелгән. Нәтиҗәдә җыеп алынган уңыш хуҗалыкларның киләчәк уңышка кадәр ашарларына җитмәгән.

Җәйге кыр- басу эшләре беткәч, кышкы чорда орчык кыру, каба-тарак тешәү, балтачылык, кисмәк ясау, чабата үрү һәм хуҗалык әйберләрен ремонтлау кебек кустарьлык эшләре белән шөгыльләнүчеләр булган. Базарчылык белән шөгыльләнә башлауга бәлки шушы һөнәрчелек сәбәп булгандыр да.

Авылда акрынлап социаль катлаулар барлыкка килә башлый. Күп хуҗалыклар бөлгенлеккә төшә һәм хәллерәк авылдашларына төрле эшләргә ялланып көн күрә. Авылның нигезен 1-2 аты, 2-3 сыеры булган урта хәлләләр тәшкил итә. Хуҗалыкларның берникадәрен хезмәтсез табышлар китерүче, башка кешеләр көченнән файдаланучы, мул тормышлылар тәшкил иткән.

Вахит авылы халкы элек-электән үзенең тырышлыгы, кәсепчелеге, һөнәрчеләре белән дан тоткан. Шунлыктан күрәмсең авылда тирә- якта дан тоткан базар эшләгән. Бу базар турында Мусина Вәсимә апа (85 яшь) сөйләгән истәлекләрдән:

“Мин үземне белә башлаганда авылда базар бар иде. Базарга Шыя тирәли урнашкан күрше-тирә авыллардан гына түгел , ә бәлки ерак дип саналган Өшен, Сасмак, Келәүеш, Акман, Чупай, Дүсмәт кебек авыллардан да киләләр иде. Базарга кунакка барган кебек киенәләр иде.Һәр авыл үзенең бер һөнәрчелеге белән дан тота һәм базарга шуны сатарга алып килә.Чупайлар кызыл балчыктан чүлмәк, күмер чүлмәге, кечкенә кувшин чүлмәкләр ясыйлар иде. Аларның чүлмәген, Чупай чүлмәге дип данлыклап саталар . Ул кызыл балчыктан , бизәкләп эшләнгән була. Өшеннәр үзләре сатып алырга киләләр иде. Җөри авыллары чана, көянтә, арба ясап алып килер иде. Алар бик җайлы, матур булырлар иде. Шәдче авылыннан юкәдән кап сугып алып киләләр иде. (Хәзерге вакытта капчык). Шыя, Каргалы, Кумырык кәрҗин, чуман (олы кәрзин кар түгә торган) алып киләләр иде. Шыя каен себеркесен (мунчанылкын) ишек алды, капка төбе себерә торган. Юкәче, Шәдчеләр юкәдән чыпта алып килерләр иде. Өскеләр шулай ук чыпта. Кумырыклар урманнан чыршы сагызы әзерләп саталар иде. Үзебезнең, Вахит авылының осталары чабата, тарак, орчык, кисмәк, куна, чәч тарагы (каен агачыннан). Мирза абый оста иде боларга. Мөхлис абый комган, мич капкачы, күмер плисәсе, күмер чүлмәге, самавыр торбасы ясап, самавырлар төзәтеп, вак-төяк тимер кораллары алып чыга иде. Мал-туар бик ишле була иде. Кемнең нинди сатасы малы бар шуны алып чыга иде.

Керәшеннәр килеп Качману, Пасха бәйрәмнәрен (Олы көн), Питрау бәйрәмнәрен шушында бәйрәм оештырып, ял итеп, күңел ачып китә торган булганнар. Гармуннар белән яшьләр, алар артыннан кызлар, яшь хатыннар, анннан өлкәннәр урам буйлап китә торганнар иде. Яшьләр булгач төрле вакыт була- кызлар өчен бер-берсе белән бәйләнешеп тә алалар. Вакыт-вакыт үзәк урамдагы өй каршында бер рәшәткә калмас иде дип искә ала көлеп Вәсимә әби. Сыер, сарык, кәҗә, каз, тавык кебек маллар булыр иде. Базар ул вакытта Вахиттә дүшәмбе, Келәүештә чәршәмбе, Лубяннықы якшәмбе булды. Пешереп күмәчләр-бәрәңге күмәче, вак бөккәннәр, вак бәлешләр алып чыгалар. Он, ярма булыр иде. Көнбагыш, чикләвек сатарлар иде стаканлап. Кишер, чөгендер, суган орлыгы сатарлар иде. Тозлаган кыяр, помидор, гөмбә кебек әйберләрне Шыя марилары алып килер иде. Свежий кыяр алып килерләр иде. Шушы базарда яшьләр узара таныша торган булганннар. Кыз урлаулар да булган. Аны сизеп алсалар артыннан куа чыга торган булганнар. Куып җитсәләр аны кире дә алып калганнар. Авыллардан сату белән кибетләр килер иде. Базар бик шәп, кирәкле чара иде. Күрше авыллар маримы, керәшенме- узара бик дус булырлар иде. Туганнар кебек бер- берсе белән кунакка йөрешерләр иде. Базарга килгәч туктап чәй эчеп, хәл алып чыгарлар иде. Нәгыймулла бабай скрипка ясар иде. Базар көнне капка төбенә чыгып уйнап утыра торган иде. Гармунчылар-Садыйков Кави, Нәгыймуллин Шәрифулла. Итекчеләр-итек басучылар Хатиф Хафизов. Юкәчеләр итек басып сатканнар, көзге сарык йонынннан. Козгынчы, Җөри, Шәдче авылларында йон тетү цехы эшләгән.

Базарный- базар хакы җыючы Хөснитдинова Хәбибҗамал булган. Аны базарник дип атаганнар. Җыелган акчаны авыл советына тапшырырга тиеш булган.

Төрле һөнәр ияләре ул вакытта да бик күп булган.Такта яручы- Мәүләви Ганиев, Хәсән Ахметшин. Йорт җиткергән кешеләргә идән- түшәмлек ярып бирә торган булганнар. Харис абый агач караваt, урындык, өстәлләр ясый торган була. Шуның өстенә әле оста гармунчы да була. Иң оста балта осталарының берсе Нурлый абый. Ул тәрәзә йөзлекләре ясарга бик оста була. Хатыны Рәхилә апаны тәрәзәдән урлап алып кайтуы белән халык телендә истә кала. Мич чыгаручыларны морҗачы

дип атаганнар. Моржачы Кашаф Насыйбуллин, Саляхов Нургали, Хаев Галиахмәт. Су тегермәне Вахитнеке - Гариф исемле кеше эшләде. Он тартып, ярма ярганнар. Ерак авыллардан да килә торган булганнар. Су ындыры суның бу ягында, Тегермән теге якта була. Инешне буып- бөяп арык аша агызып тегермән тарттырганнар. Носилкалар, атлар балчык ташып бөягәннәр. Сугыш вакытында тегермәндә, ындырда эшләп азмы- күпме тамак туйдырганнар. Урак вакыты җитсә ындырда эшлисе була дип сөенгәннәр, аны көтеп алганнар. Чөнки ындырда эшләгәндә яр буена качып арыш, борчак , бодай куырып ашаганнар."

Шушы вакыйгалардан соң күпме сулар аккан, күпме еллар үткән. Шуңа карамастан атаклы Вахит базары турында легенда кебек сөйләшүләр һаман дәвам итә.

Бүгенге көндә ярминкәләр тормышыбызда зур урын алып тора. Район күләмендә дисеңме, республикада ярминкәләр даими булып тора. Менә шулар турында муниципаль район башлыгы урынбасары Ришат Сәмигуллин болай дип яза (№20,23.03.2016 ел. "Нократ" газетасы): " Быел авыл хуҗалыгы ярминкәләре сезонын яптык, ә фермерлар үз продукцияләрен ике атнага бер тапкыр шимбә көннәрендә үзәк мәйданда тәкъдим итүне дәвам итәрләр әле. Авыл җирлекләренең барысы да чараларда актив катнаштылар, оешкан төстә уздырдылар. Күргәнегезчә, бүгенгесе дә бик күңелле бара. Халык тыгыз аралаша, товарлар сатып ала, күңел дә ача. Алдагысында Майчабу бәйрәме дә булган иде. Элекке Вахит базары күренешен дә күрдек..."

Ә "Нократ" газетасының № 87, 20 ноябрь 2013ел санында "Гөрләде Вахит базары" мәкаләсендә менә нәрсәләр язылган.

"Шәдче төбәге авыл җирлекләре мамадышлыларны үткәнгә кайтарып килделәр. Базарда ниләр генә юк: көнкүреш кирәк- яраклары, кош- кортлар, мал – туар, төрле җанварлар тиреләре, комганнар, каен, имән, ылыслы агач себеркеләре... Тартмачыклар токкан рус, мари киемендәге чибәр ханымнар, татар, керәшен, удмурт милли ризыклары тезелеп киткән өстәлләр.Сәүдә рәтләре яныннан тиз генә котылам димә: сатучылар бер алдыңа, бер артыңа төшеп, товарларын үтереп мактыйлар. Ничек инде суыра торган әтәч конфетны алмыйсың. Ул мактаудан соң тагын да балланып киткән. Төбәктәге белем һәм тәрбия бирү учреждениеләре дә үзләренең сәүдә рәтләрен сатып алучыларны җәлеп итәрлек итеп бизәгән. Башка сәүдә нокталарында да халык аз түгел иде. Әмма, ярминкәдә булганнарның берсе дә "Вахит базарына" кермичә китмәгәндер."

Менә шундый язмалар даими рәвештә матбугатта чыгып тора. Бу язмалардан күренгәнчә Вахит базары еллар үткән саен үзенең данын оныттырмыйча алдагы буыннарга җиткерә алсак иде.

**Анализ.**

Фәнни – тикшеренү эше берничә этаптан торды. Башлангыч этап икенчел мәгълүматны өйрәнүдән торды. Икенчел мәгълүмат булып Шәдче, Зур Шыя һәм Җөри урта гомуми белем бирү мәктәбләре, Көек-Ерыкса һәм Шәдче авыл җирлеге архивы һәм интернет материаллары хезмәт итте.

Беренчел мәгълүматны туплау фәнни- тикшеренү эшенең икенче этабы булды. Беренчел мәгълүмат Вахит, Ямаш, Зур Шыя, Шәдче һәм Юкәче авыллары кешеләре белән әңгәмәләр үткәрү юлы белән җыелды. Әңгәмәнең нигезен Вахит, Зур Шыя, Ямаш авыллары тарихына багышланган сораулар тәшкил итте. Нәтиҗәдә 15 респондентан мәгълүмат алынды. Өченче этапта җыелган мәгълүматка анализ һәм түбәндәге нәтиҗә ясалды:

Вахит авылының базар тарихын өйрәнеп, киләчәктә ялгышларны кабатламаска, күңелсез вакыйгалардан гыйбрәт алырга, уңышка илткәннәреннән үрнәк алырга мөмкин икәнлегенә инандым.

Базар мөнәсәбәтләре нигезендә кешеләрнең үзара мөнәсәбәтләре ята икән. Юкка гына базарны яшәешне күрсәтә торган барометр димиләр. Базар мөнәсәбәтләре белән яшәгән бу заманда дәүләтебез һәркемгә үз эшен ачу мөмкинлеге бирә. Бүгенге икътисад шартларында мәктәпләрдә конкурентлыкка сәләтле шәхес тәрбияләү бурычы алга куела.

Нәтиҗә ясап шуны әйтә алам, Мамадыш районы Вахит авылы кешеләренең тамырлары Идел Болгары дәүләте һәм Казан ханлыгы чорларына барып тоташа. Бу авылның биш гасырга якын тарихы бар. Бу вакыт эчендә илдә һәм дөньяда барган бер генә вакыйга да бу авыл вәкилләреннән башка узмаган. Шулай булгач бу авыл Россия дәүләтен төзүгә үзеннән зур өлеш керткән.

**Йомгаклау.**

Фәнни-тикшеренү эше барышында без үз алдыбызга куелган бурычларга һәм максатка ирештек. Ата-бабаларыбызның нәсел җепләрен, чыгышларын, тамырларын, аларның шөгыльләрен,

тормыш- көнкүрешләрен барладык. Без яңарыш чорында яшибез. Яңалык яшәешебезнең һәр тармагына зур тизлекләр белән үтеп керә. Кырыс базар мөнәсәбәтләре эшмәкәрләрдән көндәшлеккә сәләтле булу өчен кулланучы ихтыяҗларын сизгер тоемлау, аңа бик җитез яраклаша белүне таләп итә. Бу шартларда заманча технологияләрне гамәлгә кертү, җитештерүне яңарту юлы белән генә уңышка ирешеп була.

Киләчәккә өмет багълап, яшь буынны тәрбияләгәндә, үткән, әби-бабалалырыбыз яшәгән дәверләргә караш тоту бик мөһим. Кешене хәтер яшәтә. Халыкның тарихи хәтере кыска булса, гомере дә озын булмый аның.

Фәнни-тикшеренү эше материалларын сыйныф сәгатьләрендә, крайны өйрәнү түгәрәкләрендә, тарих атналыкларында һәм башка төрле чараларда кулланырга була.

*Файдаланылган әдәбият һәм башка чыганаклар:*


1. Р.Газизов. “ Мамадышым – язмышым”. ГУП УР “Ижевская респуб-ликанская типография», 2005
2. Ф.Гарипова. “Авылымны сөям җаным-тәнем белән”. Казан 1994 ел.
3. Вагыйз Фәсхиев язмалары.
4. Көек-Ерыкса һәм Шәдче авыл авыл җирлеге архивы.
5. Мамадыш районы Зур Шыя, Вахит, Ямаш авылы кешеләренең истәлекләре.
6. “Нократ” газетасында төрле елларда басылган язмалар.
7. Хакимов Р.С. “Атлас истории Татарстана и татарского народа”. Казань-Москва «Дрофа» 1999.
8. Шәдче, Зур Шыя һәм Җөри урта гомуми белем бирү мәктәпләре музее материаллары.
9. http://lenta.ru/news/2010/06/09/disappear/


## ИЗУЧЕНИЕ АНГЛИЙСКОГО ЯЗЫКА С НАЗВАНИЯМИ ЗАРУБЕЖНЫХ ТОВАРОВ


*Марданова Азалия, ученица 4 класса*
*Научный руководитель: Усманова Назиля Ниязовна*
*МБОУ “Изминская СОШ” Сабинского района РТ*


Мы живем в огромном удивительном мире с его разнообразием природы, стран, культур, традиций, обычаев. Язык — неотъемлемая часть культуры и мы можем и стремимся прикоснуться к иностранной культуре посредством иностранного языка. Язык — главная, основная составляющая общения. Язык — это «живой организм», который развивается, изменяется. Уже давно многие английские, слова прочно вошли в русский язык. А сегодня, благодаря международному общению, газетам, журналам, интернету и рекламе,современные слова приходят в наш родной язык и становятся привычными. Такие слова называются иноязычными заимствованиями. Многие лингвисты уделяют этому вопросу большое внимание, так как некоторые заимствованные слова приобрели социальную значимость.

В данной работе я рассмотрела заимствованные слова, которые очень часто встречаются нам в рекламе по телевизору, в магазине, когда мы покупаем товары зарубежного происхождения. Но, я выяснила, что не многие осознают, что благодаря названиям этих товаров можно узнать много английских слов и с легкостью пополнить свой словарный запас.

**Целью моей работы** является изучение и классификация названий англоязычных товаров для обогащения словарного запаса.

**Актуальность темы** исследования состоит в необходимости изучения английского языка всеми доступными средствами более легким способом.

**Цель работы**: изучить названия англоязычных товаров для обогащения словарного запаса.

**Объект исследования**: названия товаров зарубежного происхождения.

**Предмет исследования**: перевод англоязычных названий.

**Задачи**: - ознакомиться с названиями зарубежных товаров;

- выяснить, какие названия зарубежных товаров пришли к нам из английского языка;

-провести опрос среди обучающихся и педагогов школы;

-изучить их перевод или происхождение.

-составить классификацию, распределив названия по группам.

**Гипотеза**: с помощью названий зарубежных товаров можно пополнить словарный запас по английскому языку.

**Методы исследования:**

- поиск и систематизация информации из разных источников;
- опрос;
- исследование происхождения некоторых слов – названий товаров.

**Откуда в русском языке появляются иноязычные слова?**

Причины появления иноязычных слов:

- в общественной жизни появляются новые предметы, новые понятия (маркетинг, менеджер);
- появление новых слов, обозначающих явления, которые и ранее присутствовали в жизни общества, но не имели соответствующего обозначения. Обычно их существование замалчивалось. Это слова типа мафия, рэкет;
- появление нового слова обозначающего то, что прежде называлось при помощи словосочетания (рейтинг - положение фирмы, политического деятеля, передачи в списке себе подобных; имидж - образ "себя", который создает тележурналист, политический деятель, фотомодель и др.);
- изменение социальной роли предмета (офис - контора, служебное помещение, сбербанк - прежде сберкасса);
- влияние иностранной культуры, мода на иностранные слова: шоу-бизнес.

Большинство новых слов появилось с развитием науки, техники, культуры, экономики, производственных отношений. Многие из этих слов прочно входят в жизнь, утрачивают свою новизну и переходят в активный словарный запас. Например, в 50-70-е годы появляется много терминов, связанных с развитием космонавтики: *космонавт, космодром, космовидение, телеметрия, космический корабль* и др. Народная речь быстро освоила их, поскольку слова эти используются постоянно.

Новые слова появляются по-разному: одни создаются по образцу слов, уже имеющихся в языке (*автолавка, кинопанорама* и др.), другие заимствуются полностью. В-третьих, происходят преобразования значения, так что новое слово является результатом переносного употребления старого, что увеличивает его многозначность, обогащая язык. Некоторые слова от обозначения предметов, понятий, явлений перешли к их оценке.

Огромное количество заимствованных слов появилось в связи с развитием научно-технического прогресса, с завоеваниями, в связи с торговлей с другими странами.

**Какие названия товаров произошли из английского языка.**

Приходя в магазин и покупая различные товары, слушая рекламу по телевизору, мы даже не задумываемся, откуда пришли эти товары и названия. Меня заинтересовал этот вопрос. Так как я изучаю в школе английский язык, то решила пополнить свой словарный запас, выяснив, какие названия товаров имеют англоязычное происхождение.

Также мне было интересно, знают ли названия и перевод этих товаров другие ученики, поэтому я решила провести опрос среди обучающихся и учителей.

На вопрос: «Часто ли вы покупаете в магазине товары с названием, имеющим иностранное происхождение?» 100% опрошенных ответили утвердительно.

Все респонденты смогли привести примеры таких товаров.

20% знают перевод некоторых слов, 80% - не знают, 90% хотели бы узнать перевод.

По результатам опроса большинство учеников и педагогов школы хотели бы узнать перевод слов – названий зарубежных товаров.

Чтобы узнать, какие слова пришли из английского языка, я обратилась за помощью к учителю английского языка Усмановой Назиле Ниязовне. С ее помощью я составила не только список слов –

названий товаров англоязычного происхождения и перевела их, а также составила их классификацию, разделив на группы.

**Классификация слов – названий зарубежных товаров**.

Чтобы узнать перевод слов – названий зарубежных товаров англоязычного происхождения, мы обратились к словарям. Результаты нашей работы внесли в таблицу.

Некоторые продукты получили свои названия с помощью ассоциаций, которые они вызывают:

Например, skittles – это кегли, chocopie – шоколадный пирог, торт, notebook– записная книжка, Greenfield-зеленое поле (чая), nestle-гнездо, вить гнездо. (мы считаем, что это ассоциируется с нежностью, теплотой и заботой ), chocoboy-шоколадный мальчик, dove- голубь (нежность и мягкость),burn- ожог, огонь, пламя, smartphone- умный телефон, tide-прилив, волна

Следующая группа слов – это названия, произошедшие от продукта, содержащегося в товаре: nuts – орехи, popcorn – воздушная кукуруза, milky way –млечный путь, Herbal essences-травяной отвар, twix-пара печенья,

Результат: vanish – исчезновение (пятен), safeguard-безопасность (от бактерий), head and shoulders- голова и плечи (без перхоти), finish-конец (быстро справляется с мытьем посуды…)

Яркие названия для привлечения внимания покупателей: milky way –млечный путь, Alpen Gold-Альпийское золото, Bounty- щедрый подарок, red bull-красный бык, Sprite-фея, эльф, eclipse-затмение, Mountain dew- горная роса,orbit-орбита, axe- топор

Некоторые названия товаров не поддаются переводу, поэтому мы изучили их происхождение. Для этого обратились к ресурсам интернета.

Моя исследовательская работа показала, что благодаря изучению названий англоязычных товаров, вошедших в наш язык, можно узнать много английских слов и легко обогатить свой словарный запас.

В данной работе перед мною была поставлена цель – изучить названия англоязычных товаров для обогащения словарного запаса. В процессе работы я достигла поставленной цели. Изучив названия зарубежных товаров, их перевод или происхождение, выяснив, какие названия зарубежных товаров пришли к нам из английского языка, проведя опрос среди обучающихся и педагогов школы, я решила поставленные задачи.

Вскоре, на прилавках магазинов, в рекламе появятся новые товары с новыми названиями, поэтому я собираюсь продолжить эту работу, которая может принести пользу всем, кто хочет изучать английский язык и с легкостью пополнить свой словарный запас.

*Список литературы:*

1. Амосова, Н.Н.; Апресян, Ю.Д.; Гальперин, И.Р. и др.: Большой англо-русский словарь. В 2 томах 1987-1988 г.; М.: Русский язык
2. www.multitran.ru (электронный словарь)

## ТАТАР ХАЛЫК СЫНАМЫШЛАРЫНДА АГАЧ АТАМАЛАРЫНЫҢ КУЛЛАНЫШЫ

*Насыйбуллина Рәйхан, Казан шәһәре Совет районы 180 нче күп профильле полилингваль гимназиянең 4 нче Б сыйныфы укучысы*
*Фәнни җитәкче: Р.Ә.Абдуллина,*
*югары кв.категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы.*

Теләсә кайсы халык билгеле бер тирәлектә яши һәм шулай ук аны географик яктан шушы тирәлеккә яраклашкан үсемлек, хайваннар дөньясы чолгап ала. Мәсәлән, без яши торган Татарстанда катнаш һәм куе яфраклы урманнар күп. Шуңа күрә бу урманнарда үсә торган каен, нарат, имән, тал, усак кебек агачлар татар халкының сөйләмендә канатлы әйтелмәләр, тотрыклы сүзтезмәләр, мәкаль-әйтемнәр, сынамышлар составында кулланылалар.

**Эзләнү эшенең максаты**: агач атамалары кергән сынамышларны барлау.

Максатка ирешү өчен түбәндәге **бурычлар** куелды: 1) татар халык сынамышлары белән танышу, материал туплау. 2) сынамышлар арасында агач атамалары булганнарны аерып алу. 3) халык сынамышлары белән һава торышын чагыштыру. Нәтиҗә ясау.

**Эзләнү эшенең проблемасы:** экология хәлләренең кискен торуы нәтиҗәсендә сынамышларның һава торышын алдан хәбәр итүе һәрчак дөреслеккә туры килмәве.

**Гипотеза:** сынамышларны белсәк, алдагы көннәрдә нинди һава торышы булуын белергә мөмкин. **Тикшеренү эшенең объекты** – агач атамалары кергән сынамышлар.

**Тикшерү предметы** – татар фольклоры.

Кулланылган методлар: әдәби материал белән эшләү, күзәтү, чагыштыру методы.

Безнең татар халык авыз иҗаты жанрларга бик бай. Шулар арасында күләме ягыннан иң кечкенә жанрларның берсе – сынамышлар. Сынамышлар 1987 нче елда чыккан “Татар халык иҗаты” ның “Мәкальләр һәм әйтемнәр” томлыгына кертелгән, ә аерым китап булып басылып чыккан махсус җыентыклар юк. Рус халык сынамышларына караганда, татар халык сынамышлары сан ягыннан бик аз, шуның өстенә әле алар фәнни яктан өйрәнелмәгәннәр.

Сынамышлар киләчәктә һава торышының, җиләк-җимеш уңышының ничек булачагын алдан хәбәр итәләр. Мондый прогноз ясау өчен табигатьтәге һәрнәрсә игътибарга алына.

Агач атамалары кергән сынамышлар белән танышып чykkаннан соң, шартлы рәвештә аларны ике төркемгә бүләргә мөмкин: 1) ел фасылына бәйле сынамышлар 2) һәр көнгә караган сынамышлар.

Агач атамалары кергән сынамышларны барлаганнан соң түбәндәге нәтиҗәләргә киленде: Сынамышларда еш һәм сирәк кулланыла торган агач атамалары билгеле булды. Бу татар халкының нинди үсемлек тирәлегендә яшәве белән аңлатыла.

Иң күп телгә алынган агач – каен. Каен атамасы кергән 11 сынамыш булса, миләш - 6, балан, имән, чыршы атамаларын 4 әр тапкыр очраттык. Иң азы сәрби, гөлҗимеш куагы, чия телгә алына. Татар халык сынамышларында кайбер агачлар бер дә очрамый: өрәнге, тупыл, бузина, сирень, җимеш агачларыннан алмагач, карлыган, нарат агачы да сирәк “күзәтелә”. Татар фразеологиясендә тал - яратып кулланыла торган агач, ә сынамышларда ул бөтенләй урын тапмый. Эвкалипт, шелковица – тут агачы, ефәк агачы, хөрмә һ.б. агачлар татар халкы өчен үзгә агачлар, чөнки алар бары тик җылы климатта гына үсәләр. Шуңа күрә бу агачлар кергән сынамышлар безнең җирлектә киң кулланыш тапмаган.

Бабаларыбыз агачларны ел дәвамында күзәткәннәр, әмма сынамышлар күбрәк җәй һәм көз фасылына бәйле рәвештә барлыкка килгәннәр. Сынамышларның икенче төре, ягъни ел фасылына бәйле рәвештә барлыкка килгәннәре чагыштырмача күп.

Табигатьтәге үзгәрешләргә экологик факторлар да бик нык тәэсир итә, шуңа күрә сынамышларга тулысынча ышану да мөмкин хәл түгел. Бүгенге көндә сынамышлар бик аз иҗат ителә. Татар авылларында яшәүче аксакаллар ел әйләнәсендә табигатьне күзәтеп, үзгәрешләрне терки баралар. Алар хакында без “Татарстан-Яңа гасыр” телеканалында күрсәтелүче “Җир сулышы”, “Туган як” тапшыруларын карап белдек.

Чыннан да, безгә, тирә-юньнең бөтен матурлыгын күреп, күзәтеп, аны саклап яшәгәндә генә, Табигать-Ана үзенең бөек серләрен ачачак.

*Файдаланган әдәбият:*


1. Татар халык иҗаты. Мәкальләр һәм әйтемнәр. – Казан, Тат.кит.нәшр., 1987, 490-512 б.
2. Татар әдәбияты: Теория.Тарих/ Д.Ф.Заһидуллина, Ә.М.Закирҗанов, Т.Ш.Гыйләҗев, Н.М.Йосыпова. – Тулыл. 2 нче басма. – Казан: Мәгариф, 2006.
3. Әдәбият белеме. Терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге. – Казан: Мәгариф, 2007.